# И

И I *союз* — 1. һәм, белән; *папа и мама* — әти һәм әни; әти белән әни; 2. да; *русский солдат и храбр, и вынослив* — рус солдаты кыю да, чыдам да; *не хочу и подумать об этом* — бу турыда уйлыйсым да килми; 3. ләкин, мәгәр, шулай да; *всадники скрылись, и никто этого не заметил* — атлылар күздән югалды, ләкин моны берәү дә күрмәде; 4. була торып, башы белән; *мужчина, и плачет* — ир башы белән елый; ир була торып елый; 5. нәкъ... да; *о нём и говорят* — нәкъ аның турында сүз бара да; *так оно и случилось* — нәкъ шулай килеп чыкты да.

**И II** *межд.* — и! әй, ... лә! и, *полно!* — әй, җитәр лә!

**И'БИС** *м. зоол.* — ибис (җылы якларда яши торган, ләкләккә охшаган кош).

**И'БИСОВЫЙ** *зоол.* — ибис...-ы; *ибисовые перья* — ибис каурыйлары.

**И'БО** *союз* — чөнки.

**И'ВА** *ж.* — тал, өянке; *плакучая ива* — бөдрә тал, салпы тал.

**ИВА'Н-ДА-МА'РЬЯ** *ж. мн.* нет, *бот.* — ала миләүшә.

**ИВА'НОВСКИЙ** *разг. фам.:* 1) во всю **ивановскую** — көчле аваз белән, бөтен көченә; бугазы ертылганчы; *кричать во всю ивановскую* — көчле аваз белән кычкыру; бугазы ертылганчы кычкыру; 2) **ивановский червяк** *зоол. обл.* — тычкан уты (бөҗәк).

**ИВА'Н-ЧАЙ** *м. мн.* нет, *бот.* — кырлык, кырлыган.

**ИВАСЁВЫЙ**—иваси...-ы; *ивасёвая икра*— иваси икрасы.

**ИВАСИ'** *ж. нескл.*— иваси (сельдь семьялыгыннан булган вак балык, япон сардинкасы).

**И'ВИНА** *ж. обл.* — озын тал чыбыгы, өянке колга.

**ИВНЯ'К** *м. мн.* нет—1. (*заросль*) өянкелек, таллык; 2. (*прутья*) өянке чыбыклары, тал чыбыклары.

**ИВНЯКО'ВЫЙ** — өянкелекле, таллыклы, таллар үскән; *ивняковая местность* — өянкелекле урын, таллыклы урын, таллар үскән урын.

**И'ВОВЫЙ** — 1. тал...-ы; *ивовые листья* — тал яфраклары; 2. тал(дан ясалган); *ивовый плетень* — тал(дан тотылган) читән.

**И'ВОЛГА** *ж. зоол.* — шәүлегән, яңгыр теләнчесе.

**ИВЯНО'Й** *обл.* — к. ивовый.

**ИГЛА'** *ж.* — 1. энә, инә; *машинная игла* — машина энәсе; 2. (*спица для вязанья*) бишинә; 3. ылыс, чәнечке, энә; *еловые иглы* — чыршы энәләре; 4. *чаще мн.* (*колючки на теле животных*) энә, чәнечке.

**ИГЛИ'СТЫЙ** *книж.* — чәнечкеле; энәле; *иглистый кактус* — чәнечкеле кактус.

**ИГЛОВА'ТЫЙ** *разг.* — чәнечкеле; *игловатая трава* — чәнечкеле үлән.

**ИГЛОВИ'ДНЫЙ** *книж. спец.* — энә төсле, энәгә охшаган, энәсыман.

**ИГЛОДЕРЖА'ТЕЛЬ** *м. мед.* — энә тоткыч.

**ИГЛОКО'ЖИЙ** *зоол.* — энә тиреле (тиресе энәләр белән капланган).

**ИГЛООБРА'ЗНЫЙ** *книж. спец.* — к. игловидный.

**ИГНОРИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.* — игътибарсыз калдыру, әһәмият бирмәү, санга санамау; читкә кагу, исәпләшмәү, санашмау.

**ИГНОРИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд.* — игътибарсыз калдырылу, читләтелү, читкә кагылу.

**И'ГО** *ср. мн. нет* — авырлык, кысу, изү, җәбер, золым, иго; *свергнуть иго капитала* — капитал изүен бәреп төшерү.

**ИГО'ЛКА** *ж.* — к. игла. 1. ◇ **Сидеть, как на иголках** — тынычсыз утыру, борчылып, куркып утыру (нинди дә булса күңелсезлек көтүдән). **До иголки** *разг. устар.* — энәсеннән җебенә кадәр.

**ИГО'ЛОЧКА** *ж. разг.* — к. иголка. ◇ **С иголочки** *разг.* — өр-яңа, энәдән-җептән чыккан, әле генә инәдән төшкән (яңа гына тегелгән кием турында); *одет с иголочки* — өр-яңадан киенгән; *костюм у него с иголочки* — аның костюмы өр-яңа, аның костюмы энәдән-җептән генә чыккан.

**ИГО'ЛОЧНИК** *м.* — 1. к. игольник 1; 2. *спец.* энәче, энә ясаучы.

**ИГО'ЛОЧНЫЙ** — энә...-ы; *иголочное производство* — энә производствосы.

**ИГО'ЛЬНИК** *м.* — 1. энә савыты яки мендәре (энәләр кадап куя торган мендәр); 2. *только ед. собир.* коелган ылыс.

**ИГО'ЛЬНИЦА** *ж. разг.* — к. игольник 1.

**ИГО'ЛЬНЫЙ** —энә...-ы; *игольное ушко*— энә күзе; *игольная мастерская* — энә мастерское.

**ИГО'ЛЬЧАТЫЙ** *спец.* — энәле; энәләрдән тора торган; *игольчатый барабан* — энәле барабан.

**ИГО'ЛЬЩИК** *м. спец.* — энәче (энә производствосында эшләүче).

**ИГО'РНЫЙ** — комарлы уен...-ы; азартлы уеннар...-ы; *игорная зала* — комарлы уен залы, азартлы уеннар залы (карта, рулетка уеннары кебек азартлы уеннар уйнау залы).

**ИГРА'** *ж.* — 1. уйнау; *игра в шахматы* — шахмат уйнау; 2. уен; *детские игры* — балалар уеннары. ◇ **Раскрыть игру** (*чью*) битлеген ачу (кемнең дә булса берәүнең яшерен ниятләрен, уйларын ачу, фаш итү). **Опасная игра** *перен.* — куркыныч эш, тәвәккәллеккә корылган эш. **Игра слов** — сүз уйнату, каламбур (сүзләрнең бер мәгънәсен икенчесе урынына куллану). **Игра природы** — табигатьнең шаяруы, гариплек. **Игра судьбы** *книжн.* — язмышның шаяруы (тормышта көтелмәгән борылыш, вакыйга). **Игра случая** — уйланмаган, көтелмәгән хәл, очрак. **Игра воображения** *ирон.* — буш фантазия, уйдырма, ялган. **Игра не стоит свеч** — биш тиенлек куян, ун тиенлек зыян.

**ИГРА'ЛИЩЕ** *ср. книжн. устар.* — 1. уен урыны; 2. уенчык, курчак (берәр көч кулында, ихтыярында).

**ИГРА'ЛЬНЫЙ** — уен...-ы; *игральные карты* — уен картасы.

**ИГРАНУ'ТЬ** *однокр. простореч.* — уйнап алу.

**ИГРА'ТЬ** *несов.* — 1. уйнау; *дети весь день играли в саду* — балалар көн буе бакчада уйнадылар; *играть в футбол* — футбол уйнау; *играть в прятки* — качышлы уйнау; 2. башкару; уйнау; *пианист играл Шуберта* — пианист Шуберт әсәрләрен башкарды; *играть на скрипке* — скрипкада уйнау, скрипка уйнау; 3. уйнау, шаяру; *играть с огнём* — ут белән уйнау; ут белән шаяру; *играть с судьбой* — язмыш белән шаяру; 4. *перен.* уйнау, җемелдәү, балку; *солнце играет на поверхности воды* — су өстендә кояш җемелди; *румянец играет на его щеках* — яңакларында кызыллык балкый; 5. кылану; *играть в великодушие* — киң күңелле булып кылану. ◇ **Играть в молчанку** *разг. шутл.* — үзара сөйләшмичә һәм сорауларга җавап бирмичә утыру. **Играть в прятки** *перен.* — берәр нәрсәне яшерү, сер итеп тоту. **Играть в загадки** *разг.* — читләтеп сөйләү, сүзне әйтеп бетермичә уйланырга мәҗбүр итү. **Играть свадьбу** *обл.* — туй үткәрү, туй ясау. **Играть опасную игру** — тәвәккәллеккә бару, ни булса шул булыр дип эшләү. **Играть первую скрипку** — 1) оркестрда беренче скрипкада уйнау; 2) *перен. разг.* нинди дә булса бер эштә, вакыйгада сүзе үтемле, авторитетлы булу, җитәкче кеше булу. **Играть комедию** *разг. перен.* — алдау, хәйләләү, икейөзлеләнү, рыялану, кылану. **Играть глазами** — күз уйнату, мәгънәле итеп, җанлы итеп карау. **Играть словами** — сүз уйнату.

**ИГРА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. *страд.* уйналу; *роль Хлестакова сегодня играется приезжим гастролёром* — бүген Хлестаков роле читтән килгән гастролёр тарафыннан уйнала; 2. *безл.* уйныйсы килү; *мне что-то сегодня не играется* — бүген минем нигәдер уйныйсым килми; 3. *обл.* уйнау; *дети играются в саду* — балалар бакчада уйныйлар.

**ИГРА'ЮЧИ** *нареч.* — уйнап кына, көч куймыйча гына, җиңел генә, уйнаган кебек кенә; *написать статью играючи* — мәкаләне җиңел генә (уйнап кына) язып ташлау.

**ИГРА'ЮЩИЙ** — 1. уйнаучы, уйный торган; 2. *в знач. сущ.* уенчы, уйный белүче, уен остасы; *собралось много играющих* — күп уенчы җыелды; *среди присутствующих не оказалось ни одного играющего* — килгән кешеләр арасында бер генә дә уйный белүче юк иде.

**И'ГРЕК** *м.* — игрек (1. француз алфавитында соңгы хәреф алдындагы хәрефнең (*у* хәрефенең) исеме; 2. математикада „*у*" хәрефе белән билгеләнә һәм эзләнә торган билгесез зурлык).

**ИГРЕ'НЕВЫЙ, ИГРЕ'НИЙ** *спец.* — чаптар (ат төсе).

**ИГРЕ'Ц** *м.* — 1. *устар.* музыкант; 2. *простореч. шутл.* к. игрок. ◇ **Швец и жнец, и в дуду игрец** *разг. ирон.* — бөтен эш кулыннан килә, алтын куллы, эшләмәгән эше юк.

**ИГРЕ'ЦКИЙ** — уенчы...-ы, уенчыга гына хас; *игрецкий азарт* — уенчыга гына хас азарт.

**ИГРИ'ВЫЙ** — 1. уенчак, шаян, шук (уйнарга ярата торган); *игривый котёнок* — уенчак песи баласы; 2. шаярулы, уен катыш; *игривая улыбка* — шаярулы елмаю; 3. *разг.* әдәпсез, оятсыз; *анекдот игривого свойства* — әдәпсез анекдот.

**ИГРИ'СТЫЙ** — күбекләнеп тора торган, чемердәп тора торган; *игристый квас* — чемердәп тора торган квас.

**ИГРОВО'Й** *спец.* — уен...-ы; *игровые песни* — уен җырлары.

**ИГРО'К** *м.* — 1. уенга катнашучы, оста уйнаучы, уенчы; *в футбольной команде 11 игроков* — футбол командасында 11 уенчы; 2. уен сөючән кеше; уен яратучы, уен яратучан кеше, уенга һәвәс; 3. *перен. разг.* тәвәккәл кеше, азартлы кеше; *он игрок по своей натуре* — ул үзенең табигате белән тәвәккәл кеше.

**ИГРУ'Н** *м.*, **ИГРУ'НЬЯ** *ж. разг.* — уенчак, шаян, шук.

**ИГРУ'ШЕЧНИК** *м.* — уенчык ясаучы, уенчыклар мастеры.

**ИГРУ'ШЕЧНЫЙ** — 1. уенчыклар...-ы; *игрушечный магазин* — уенчыклар магазины; 2. уенчык...; *игрушечный паровоз* — уенчык паровоз; 3. уенчыктай, уенчык хәтле генә, бик кечкенә (нормаль күләмнән кечкенәрәк булган әйбер); *лошадь-то совсем игрушечная* — аты бөтенләй уенчыктай гына.

**ИГРУ'ШКА** *ж.* — 1. уенчык; *детская игрушка* — балалар уенчыгы; 2. уен; юаныч, күңел ачкыч; *жизнь не игрушка, а сложное и трудное дело* — тормыш — уен түгел, бәлки авыр һәм катлаулы нәрсә;

3. *перен.* уенчык (башкалар кулында тыңлаучан корал); *он был игрушкой в руках заговорщиков* — ул заговорчылар кулында уенчык иде; 4. *разг.* уенчык кебек, нәкъ уенчык шикелле, уенчыкмыни (матур, нәфис итеп эшләнгән әйбер); *паровоз выпустили — прямо игрушка!* — паровоз эшләп чыгарганнар — уенчыкмыни!

**И'ГРЫВАТЬ** *многокр. устар. разг.* — уйнаштыргалау.

**ИГУ'МЕН** *м. церк.* — игумен (ирләр монастыре башлыгы).

**ИГУ'МЕНСКИЙ** *церк.* — игуменлык ...-ы; игумен...-ы; *игуменский сан* — игуменлык дәрәҗәсе.

**ИГУ'МЕНСТВОВАТЬ** *несов. церк.* — игуменлык итү, игумен булып эшләү.

**ИГУ'МЕНЬЯ** *ж. церк.* — игуменья (хатын-кызлар монастыре башлыгы).

**ИДЕА'Л** *м. книж.* — 1. идеал (бөек максат, омтылышлар һәм максатларның иң югары чиге; *высокие идеалы коммунизма* — коммунизмның бөек максатлары); 2. иң камил үрнәк; *идеал доброты* — яхшылыкның иң камил үрнәге.

**ИДЕАЛИЗА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *книж.* — к. идеализировать.

**ИДЕАЛИЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. книж.* — идеаллаштыру (чынбарлыкта булганына караганда бик күп югары итеп күз алдына китерү); *идеализировать людей* — кешеләрне идеаллаштыру.

**ИДЕАЛИЗИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. страд. книж.* — идеаллаштырылу.

**ИДЕАЛИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *филос.* — идеализм (1. материализмга капма-каршы булган реакцион философик юнәлеш; идеализм бөтен барлыкның нигезе итеп материяне түгел, бәлки рухны, идеяне таный; 2. чынбарлыкны идеаллаштыру).

**ИДЕАЛИ'СТ** *м.*, **ИДЕАЛИ'СТКА** *ж.* — идеалист (1. идеализм тарафдары, идеалистик философия тарафдары; 2. нинди дә булса бер эшкә, идеягә турылыклы хезмәт итүче кеше; 3. чынбарлыкны идеаллаштыручы, хыялга бирелүчән кеше).

**ИДЕАЛИСТИ'ЧЕСКИЙ** *книж.* — идеалистик; *идеалистическая философия* — идеалистик философия; *идеалистическая точка зрения* — идеалистик караш.

**ИДЕАЛИСТИ'ЧНЫЙ** *книж.* — идеалистик философия белән сугарылган, идеализм белән сугарылган.

**ИДЕА'ЛЬНО** *нареч.* — 1. бик яхшы, бик оста; *он идеально играет в шахматы* — ул шахматны бик яхшы уйный; 2. чик дәрәҗәдә, бик, чиктән тыш; *идеально честный человек* — бик намуслы (гадел) кеше.

**ИДЕА'ЛЬНЫЙ** — 1. идеаль; *идеальная любовь* — идеаль мәхәббәт; *идеальный тип* — идеаль тип; 2. бик яхшы, бик шәп, үрнәк булырлык; *идеальный работник* — үрнәк булырлык работник, бик шәп работник; *идеальные квартирные условия* — бик яхшы квартира шартлары.

**ИДЕ'ЙКА** *ж. пренебр.* — әһәмиятсез идея, вак идея, идея кисәге; *у него в голове две-три идейки, схваченные из брошюрок, а больше ничего нет* — аның башында брошюралардан отып алынган ике-өч идея кисәгеннән башка берни дә юк.

**ИДЕ'ЙНЫЙ** — 1. идея ...-ы; *идейное содержание книги* — китапның идея эчтәлеге; 2. идеяле (нинди дә булса бер идея белән сугарылган); *идейное искусство* — идеяле сәнгать; 3. алдынгы идеяле, алдынгы идеяләргә бирелгән, идеягә чын күңелдән бирелгән.

**ИДЕНТИФИКА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *науч.* — к. идентифицировать.

**ИДЕНТИФИЦИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов., науч.* — охшату, бердәй санау, тиңләштерү.

**ИДЕНТИФИЦИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов., книж.* — охшатылу, бердәй саналу, тиңләштерелү.

**ИДЕНТИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — бердәйлек, охшашлык, тиңдәшлек.

**ИДЕНТИ'ЧНЫЙ** *книж.* — бердәй, охшаш, тиңдәш.

**ИДЕОГРА'ММА** *ж. филол.* — идеограмма (тулы бер сүзне яки тулы бер төшенчәне аңлата торган язма билге, мәсәлән, саннар, тапкырлау, бүлү билгеләре һ. б.).

**ИДЕОГРАФИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *филол.* — идеографизм (төшенчәләрне идеограммалар ярдәмендә аңлату ысулы).

**ИДЕОГРАФИ'ЧЕСКИЙ** *филол.* — идеографик; *идеографическое письмо* — идеографик язма (язу).

**ИДЕОГРА'ФИЯ** *ж. мн.* нет, *филол.* — идеография (идеограммалар ярдәмендә язу системасы).

**ИДЕО'ЛОГ** *м. книж.* — идеолог (җәмгыятьтәге аерым бер сыйныфның яки иҗтимагый группаның идеологиясен нигезләүче, яклаучы; шул фикер агымының башында торучы).

**ИДЕОЛОГИ'ЧЕСКИ** *нареч.* — идеологик яктан; *идеологически выдержанная пьеса* — идеологик яктан тотнаклы пьеса.

**ИДЕОЛОГИ'ЧЕСКИЙ** — идеологик, идеология...-ы; *идеологические разногласия* — идеологик каршылыклар.

**ИДЕОЛО'ГИЯ** *ж. книж.* — 1. идеология (билгеле бер сыйныфның иҗтимагый аңы, дөньяга карашы һәм фикерләр системасы); *пролетарская идеология* — пролетариат идеологиясе; 2. идея эчтәлеге, философик юнәлеш; *идеология книги* — китапның идея эчтәлеге.

**ИДЁТ** — 1. риза, бик яхшы, ярый; *едем?— Идёт!* — барабызмы? — Ярый, яхшы! 2. *(об одежде, обуви)* бик килешә.

**ИДЕ'Я** *ж.* — 1. идея (а. предмет яки күренеш турында уй, фикер, төшенчә; б. идеалистик философиядә — әйбернең, күренешләрнең мәңгелек, даими асылы); 2. идея, төп фикер, төп уй, төзелеш принцибы; *идея романа* — романның идеясе (төп фикере); *мне стала известна идея этой машины* — бу машинаның төзелеш принцибы миңа аңлашылды; 3. идея, уй, фикер; *он первый подал эту идею* — ул бу фикерне (идеяне) беренче булып әйтте. ◇ **Навязчивая идея** — бәйләнчек идея (һаман баштан чыкмый торган фикер, уй).

**ИДИ'ЛЛИК** *м. лит.* — идиллик, идиллияләр авторы.

**ИДИЛЛИ'ЧЕСКИЙ** — 1. идиллия...-ы; *идиллический жанр* — идиллия жанры; 2. *ирон.* идиллик; тыныч, гаугасыз, борчылусыз; *идиллическое настроение* — идиллик настроение, тыныч настроение.

**ИДИЛЛИ'ЧНЫЙ** *ирон.* — идиллик, гаугасыз, борчылусыз.

**ИДИ'ЛЛИЯ** *ж.* — идиллия (1. *лит.* табигать кочагындагы гамьсез тормышны идеаллаштырып сурәтләгән шигъри әсәр; 2. *шутл.* тыныч, гаугасыз, борчылусыз семья тормышы).

**ИДИО'М** *м.*, **ИДИО'МА** *ж. лингв.* — идиом, идиома (берәр телгә хас булган һәм бүтән телгә сүзгә-сүз тәрҗемә ителми торган фразеологик әйтем, мәсәлән, „калган эшкә кар ява").

**ИДИОМАТИ'ЗМ** *м. лингв.* — к. идиома.

**ИДИОМА'ТИКА** *ж. лингв.* — идиоматика (1. идиомалар турында тәгълимат; 2. нинди дә булса бер телдәге идиомалар җыелмасы).

**ИДИОМАТИ'ЧЕСКИЙ** *лингв.* — идиоматик; *идиоматическое выражение* — идиоматик әйтем.

**ИДИОМАТОЛО'ГИЯ** *ж.* — идиоматология (тел белеменең идиомаларны тикшерә торган бүлеге).

**ИДИОСИНКРА'ЗИЯ** *ж. мед.* — идиосинкразия (1. организмның кайбер ярсыткычларга, авыруларча реакция ясавыннан гыйбарәт булган индивидуаль үзенчәлеге, мәсәлән, итне күрү яки итнең исе борынга керү белән күңел болгана башлау; 2. берәр нәрсәгә, мәсәлән, берәр даруга яки ашый торган әйбергә, авыруларча нәфрәт яки авыруларча һәвәслек).

**ИДИО'Т** *м.* — 1. *мед.* идиот, акылга зәгыйфь (кеше), дивана; 2. *разг. бран.* идиот (ахмак, юләр, тинтәк).

**ИДИОТИ'ЗМ** I *м., мн.* нет — 1. *мед.* идиотизм, тумыштан акылга зәгыйфьлек, диваналык, тума юләрлек; 2. *разг.* (*глупость*) мәгънәсезлек, ахмаклык, ангыралык.

**ИДИОТИ'ЗМ** II *м. устар.* — к. идиома.

**ИДИО'ТИНА** *м.* и *ж. простореч. бран.* — юләр, ангыра, тинтәк.

**ИДИОТИ'ЧЕСКИЙ** — 1. идиот ...-ы, идиотлык ...-ы; *идиотический вид* — идиот кыяфәте; 2. идиотларча; *идиотическое поведение* — үзеңне идиотларча тоту.

**ИДИО'ТКА** *ж.* — к. идиот.

**ИДИО'ТСКИЙ** — 1. идиотларча; *идиотский смех* — идиотларча көлү; 2. *разг.* мәгънәсез, ахмак, юләр; *что за идиотская мысль пришла тебе в голову?* — нәрсә соң синең башыңа шундый ахмак уй төште?

**ИДИО'ТСТВО** *ср. разг.* — идиотлык, ахмаклык, мәгънәсезлек; идиотларча мөгамәлә, идиотларча эш итү; *такого идиотства никто не ожидал от него* — мондый ахмаклыкны аннан беркем дә көтмәгән иде.

**И'ДОЛ** *м.* — 1. *рел.* пот, санам, сын, торataш; *поклонение идолам* — потларга (санамнарга) табыну; 2. *простореч. бран.* бүкән, ахмак; 3. *устар.* кадерле, хөрмәтле (әйбер, кеше). ◇ **Стоять или сидеть идолом** *разг.* — селкенмичә, торataш кебек басып яки утырып тору.

**ИДОЛОПОКЛО'ННИК** *м. рел., этнол.* — потка табынучы, сынга табынучы.

**ИДОЛОПОКЛО'ННИЧЕСКИЙ** *рел., этнол.* — сынга табыну ...-ы; *идолопоклоннические культы* — потка (сынга) табыну йолалары.

**ИДОЛОПОКЛО'НСТВО** *ср. мн.* нет — 1. *рел. этнол.* потка табыну, сынга табыну; 2. *перен. неодобр.* артык олылау, сукырларча табыну.

**ИДТИ'** (и **И'ТИ**) *несов.* — 1. (*туда*) бару; *дети идут в школу* — балалар мәктәпкә баралар; (*сюда*) килү; *к нам идёт какой-то человек* — безгә таба ниндидер кеше килә; (*домой*) кайту; *я иду домой* — мин өйгә кайтам; 2. бару; *идти в гости* — кунакка бару; 3. (*о льде*) агу, китү; *лёд идёт* — боз ага, боз китә; 4. (*о крови, гное*) агу, килү; *из раны идёт гной* — ярадан эрен килә; 5. кабу; *окунь хорошо идёт на червяка* — алабуга селәүчәнгә яхшы каба; 6. яву; *дождь идёт* — яңгыр ява; 7. йөрү, эшләү; *часы идут верно* — сәгать дөрес йөри; *мотор идёт хорошо* — мотор яхшы эшли; 8. үтү, узу; *за днями идут дни, идёт за годом год* — көннәр артыннан көннәр үтәләр, ел артыннан ел үтә; 9. бару; *идут переговоры* — сөйләшүләр бара; *идёт бой* — сугыш бара; 10. чыгу, күтәрелү; *из печи идёт дым* — мичтән төтен чыга; 11. бару, уйналу; *эта пьеса шла в прошлом сезоне* — бу пьеса үткән сезонда барган иде; 12. таралу, йөрү; *сплетни идут* — гайбәт тарала; *слух идёт* — хәбәр йөри; 13. *разг.* керү; *гвоздь не идёт в стену* — кадак стенага керми; *нитка не идёт в иголку* — җеп энәгә керми; 14. *разг. устар.* бару; *ваш сын хорошо идёт по математике* — сезнең улыгыз математикадан яхшы бара; 15. бару, күнү; *идти на все условия* — бөтен шартларга күнү; 16. *перен.* килү; *сон не идёт* — йокы килми; 17. сатылу, үтү; *книга хорошо идёт* — китап яхшы сатыла; 18. китү, тотылу; *на костюм идёт три метра материи* — костюмга өч метр материя китә; 19. килешү; *ей очень идёт красный цвет* — аңа кызыл төс бик килешә; 20. йөрү, чыгу; *идти королём* — корольдән йөрү, король белән йөрү (шахмат яки карта уенында); 21. китү; *идти в обработку* — эшкәртүгә китү; *идти в продажу* — сатылуга китү; 22. *простореч.* башлау; *идти в пляс* — бии башлау. ◇ **Идти в сравнение** — чагыштырылу. **Температура идёт на понижение** — температура төшә. **Куда ни шло** — булмаса булган икән, ни булса булыр. **Идти ко дну** — 1. төпкә китү, бату; 2. *перен.* һәлак булу. **Идти в гору** *перен.* — югары менү, күтәрелү, алга китү. **Идти впрок** — файдага ярау, файдага китү. **Не идти с ума** — баштан чыкмау, онытмау, хәтерләү. **Идти в народ** *истор.* — халыкка китү (политик агитация алып бару өчен народникларның халык белән аралашулары).

**ИЕЗУИ'Т** *м. книж.* — 1. иезуит (католиклар монахы, прогресс һәм демократия белән көрәштә үзенең максатларына ирешү өчен иң кабахәт чаралардан да тартынмый торган иң кара реакциянең, Рим папасының терәге булган „Иисус җәмгыятенең" члены); 2. *перен. (лицемер)* икейөзле кеше, хәйләкәр кеше, монафыйк.

**ИЕЗУИТИ'ЗМ, ЕЗУИТИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *книж.* — к. иезуитство.

**ИЕЗУИ'ТСКИЙ, ЕЗУИ'ТСКИЙ** *книж.* — 1. иезуитлар...-ы; *иезуитский монастырь* — иезуитлар монастыре; 2. *перен.* иезуитларча, монафыйкларча; *иезуитский поступок* — иезуитларча эш итү, монафыйкларча эш итү.

**ИЕЗУИ'ТСТВО, ЕЗУИ'ТСТВО** *ср. мн.* нет, *книж.* — иезуитлык, икейөзлелек, хәйләкәрлек, принципсызлык, монафыйклык.

**ИЕЗУИ'ТСТВОВАТЬ, ЕЗУИ'ТСТВОВАТЬ** *несов. книж.* — иезуитларча мөгамәлә итү, иезуитларча кылану, монафыйкларча кылану.

**ИЕРО'ГЛИФ** *м.* — иероглиф (1. *лингв.* кытайлар язуында, борынгы мисырлылар язуында тулы бер төшенчәне яки аерым иҗекне белдерә торган шартлы билгеләр; 2. *перен.* танымаслык, буталчык язу).

**ИЕРОГЛИФИ'ЧЕСКИЙ** *лингв.* — иероглифик; *иероглифическое письмо* — иероглифик язу.

**ИЖДИВЕ'НЕЦ** *м.*, **ИЖДИВЕ'НКА** *ж.* — иждивенец, иждивенка (кемнең дә булса тәрбиясендә торучы).

**ИЖДИВЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет: **на иждивении** — иждивениесендә, тәрбиясендә; *на иждивении брата* — абыйсы тәрбиясендә.

**ИЖДИВЕ'НСКИЙ** и **ИЖДИВЕ'НЧЕСКИЙ** — иждивенецлык...-ы, иждивенкалык...-ы; *иждивенческое настроение* — иждивенецлык (иждивенкалык) настроениесе (үз көчләренә түгел, бәлки читтән булган ярдәмгә исәп тоту).

**ИЖДИВЕ'НСТВО** *ср. мн.* нет — иждивенецлык, иждивенкалык, ...-нең тәрбиясендә тору; *справка об иждивенстве* — ...-нең тәрбиясендә тору турында справка.

**ИЗ** *предлог с род. п.* — 1. ...-дан, ...эченнән; *выйти из воды* — судан чыгу; 2. ...-дан; *выходить из употребления* — кулланудан чыгу; *узнать из газет* — газеталардан белү; *из достоверных источников* — ышанычлы чыганаклардан; *дом построен из камня* — өй таштан салынган; 3. ...-дан, ...-нын; *младший из братьев* — туганнардан иң кечесе; туганнарның иң кечесе; *трус из трусов* — куркакларның (да) иң куркагы; 4. ... йөзеннән; *из уважения к заслугам кого-н.* — кемнең дә булса хезмәтләренә хөрмәт йөзеннән. ◇ **Стараться изо всех сил** — бөтен көчне куеп тырышу.

**ИЗБА'** *ж.* — өй, агач өй. ◇ **Изба-читальня** — уку өе.

**ИЗБА'БИТЬСЯ** *сов. простореч. презрит.* — җебү, изрәү (йомшак характерлы ирләр турында).

**ИЗБАВИ'ТЕЛЬ** *м.*, **ИЗБАВИ'ТЕЛЬНИЦА** *ж.* — саклап калучы, йолып алучы, коткаручы.

**ИЗБА'ВИТЬ** *сов.* — коткару, алып калу, саклап алып калу, йолып алып калу; *избавить от смерти* — үлемнән алып калу. ◇ **Избавь, избавьте** — тынычлыкта калдыр(ыгыз), борчыма(гыз); *сам иди, а меня избавь* — үзең бар, ә мине тынычлыкта калдыр (борчыма). **Избави бог** — алла сакласын.

**ИЗБА'ВИТЬСЯ** *сов.* — котылу, котылып калу, сакланып калу; *избавиться от опасности* — куркынычтан котылу.

**ИЗБАВЛЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — 1. к. избавить, избавиться; 2. азатлык; *никто не даст нам избавления: ни бог, ни царь и ни герой* — патша да, алла да, батыр да — бирмәс азатлык берсе дә.

**ИЗБАВЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. избавить.

**ИЗБАВЛЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. избавиться; 2. *страд.* коткарылу, йолып алыну.

**ИЗБАЛО'ВАННОСТЬ** *ж. мн.* нет — иркәлек, иркә булу, иркәләп бозылган булу; *девочка, несмотря на избалованность, была очень прилежна* — кыз, иркә булуына карамастан, бик тырыш иде.

**ИЗБАЛОВА'ТЬ** *сов.* — иркәләп бозу, узындыру; *ребёнка избаловали сами родители* — баланы ата-анасы үзләре иркәләп бозган.

**ИЗБАЛОВА'ТЬСЯ** *сов.* — иркәләнеп бозылу, тыйнаксызлану.

**ИЗБАЛО'ВЫВАТЬ** *несов. разг.* — к. избаловать.

**ИЗБАЛО'ВЫВАТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. *несов.* к. избаловаться; 2. *страд.* иркәләп узындырылу.

**ИЗБА'Ч** *м.* — избач, уку өе җитәкчесе, уку өе мөдире.

**ИЗБЕ'ГАТЬ** *сов.* — йөгереп йөреп чыгу, күп җирләрдә булу; *избе́гал за день весь город* — бер көндә бөтен шәһәрне йөгереп йөреп чыктым.

**ИЗБЕГА'ТЬ** *несов. разг.* — 1. сакланып калу, котылып калу; *ни один преступник не избегает наказания* — бер генә җинаятьче дә җәзадан котылып калмый; 2. качу, күренмәскә тырышу, тайпылу, тайпылып калу; *он избегал неприятных разговоров* — ул күңелсез сөйләшүләрдән кача иде.

**ИЗБЕ'ГАТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. *(устать от беготни)* күп йөгереп арү, йөгереп хәлдән таю, әлсерәп бетү; 2. *(стать непослушным) фам.* кулдан ычкыну, тыңламый башлау, бозылу, үзсүзләнеп китү (балалар турында).

**ИЗБЕ'ГНУТЬ** *сов.* — к. избежать.

**ИЗБЕЖА'НИЕ:** во избежание — булмасын өчен, булмасын дип; *во избежание лишних расходов* — артык расходлар булмасын дип.

**ИЗБЕЖА'ТЬ** *сов.* — к. избегáть.

**ИЗБЁНКА** *ж. разг. уничижит.* — кечкенә өй, начар өй.

**ИЗБИВА'ТЬ** *несов.* — к. избить 1, 2.

**ИЗБИВА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. избиться; 2. *страд.* кыйналу, кыйнап ташлану; кырып бетерелү.

**ИЗБИЕ'НИЕ** *ср. книж.* — 1. кыйнау; 2. үтерү, кыру.

**ИЗБИРА'ЕМОСТЬ** *ж. мн. нет* — сайлану хокукы.

**ИЗБИРА'ТЕЛЬ** *м.*, **ИЗБИРА'ТЕЛЬНИЦА** *ж.* — сайлаучы.

**ИЗБИРА'ТЕЛЬНЫЙ** — сайлау...-ы; *избирательный закон* — сайлау законы; *избирательное право* — сайлау хокукы.

**ИЗБИРА'ТЬ** *несов.* — сайлау.

**ИЗБИРА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — сайлану.

**ИЗБИ'ТОСТЬ** *ж. мн. нет, перен.* — искергәнлек, күп чәйнәлгәнлек, күп кабатланганлык; *избитость фраз* — фразаларның күп чәйнәлгәнлеге.

**ИЗБИ'ТЫЙ** — 1. тукмалган, изелгән, ватылган, кыйналган; *избитая девочка* — кыйналган кыз бала; 2. *перен.* искергән, күп чәйнәлгән, күп кабатланган; *избитая тема* — күп чәйнәлгән тема.

**ИЗБИ'ТЬ** *сов.* — 1. кыйнау, кыйнап ташлау, тукмау, тукмап ташлау; 2. *книж.* кыру, кырып бетерү; *варвары избили всё население поголовно* — варварлар барлык халыкны кырып бетергәннәр; 3. яньчеп бетерү, бозып бетерү; *необходимо переложить яблоки соломой, чтобы не избить в дороге* — юлда яньчеп бетермәс өчен (юлда яньчелеп бетмәсен өчен), алмаларны салам белән аралаштырып салырга кирәк.

**ИЗБИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. бәрелеп бетү, сугылып бетү; бәрелеп-сугылып бетү; 2. тузып бетү, бозылып бетү, эштән чыгу; *сапоги избились* — күн итек тузып беткән.

**ИЗБИЧЕВА'ТЬ** *сов. устар.* — камчылау; камчы белән кыйнау, камчы белән кыйнап ташлау.

**ИЗБЛЕВА'ТЬ** *сов.* — 1. *устар.* косып чыгару; *изблевать пищу* — ашаган азыкны косып чыгару; 2. *простореч. вульг.* (*испачкать рвотой*) косып пычрату, косып пычратып бетерү. ◇ Изблевать хулу *на кого-нибудь ритор. устар.* — кемгә дә булса пычрак ташлау, әшәке сүзләр әйтү.

**ИЗБЛЁВЫВАТЬ** *несов.* — к. изблевать.

**ИЗБЛЁВЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. *устар.* косып чыгарылу; 2. *вульг.* косып пычратылу.

**ИЗБНО'Й** *спец.* — өй...-ы; *избная дверь* — өй ишеге.

**ИЗБОДА'ТЬ** *сов.* — сөзеп яралау, сөзеп яралап бетерү.

**ИЗБО'ИНА** *ж. мн. нет* — сыгынты, түп; *подсолнечная избоина* — көнбагыш түбе.

**ИЗБОЛЕ'ТЬ** *сов. простореч.* — әрнү, әрнеп бетү; *всё сердце изболело за него* — аның өчен йөрәгем әрнеп бетте.

**ИЗБОЛЕ'ТЬСЯ** *сов. простореч.* — к. изболеть.

**ИЗБОЛТА'ТЬ** *сов. обл.* — (туглый-туглый) бозып бетерү; *изболтать мутовку* — (туглый-туглый) болгаткычны бозып бетерү.

**ИЗБОЛТА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. эшсез йөреп бозылу, күзәтүчесез йөреп бозылу; 2. *презрит.* күп сөйләп түбән китәрү; *адвокат изболтался* — адвокат күп сөйләп түбән китәрде.

**ИЗБО'РНИК** *м. истор. лит.* — кульъязма җыентык (борынгы Русьта төрле тарихи китаплардан сайлап алынган мәкаләләрдән тора торган кульъязма җыентык).

**ИЗБОРОЗДИ'ТЬ** *сов.* — 1. ергалап бетерү; *овраги избороздили поле* — коры елгалар басуны ергалап бетергән; 2. *перен.* аркылыга буйга йөреп чыгу; *охотник избороздил все леса севера* — аучы барлык төньяк урманнарын аркылыга-буйга йөреп чыкты. ◇ Морщины избороздили лоб *перен.* — маңгае җыерчыклар белән капланган.

**ИЗБОЧЕ'НИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — к. избочениться.

**ИЗБОЧЕ'НИТЬСЯ** *сов. разг.* — бөергә таяну, билгә таяну.

**ИЗБОЧИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — к. избочениться.

**ИЗБРА'НИЕ** *ср. книж.* — сайлау; *избрание делегатом* — делегат итеп сайлау.

**ИЗБРАНИ'ТЬ** *сов. разг.* — сүгеп ташлау, каты итеп сүгеп ташлау.

**ИЗБРА'ННИК** *м.*, **ИЗБРА'ННИЦА** *ж. книж. ритор.* — 1. сайланган кеше; *народный избранник* — халык тарафыннан сайланган кеше; 2. сөекле, сөекле кеше; *она всю жизнь оставалась верна своему избраннику* — ул үзенең сөеклесенә гомере буена турылыклы булып калды; 3. (*особо одарённый, избранный человек*) аеруча сәләтле кеше, аеруча талантлы кеше.

**И'ЗБРАННЫЕ** *мн. в знач. сущ.* — сайланганнар (буржуаз-дворяннар җәмгыятендә үзләренең җәмгыятьтә тоткан урыннары белән башкалардан аерылып торучылар).

**И'ЗБРАННЫЙ** *книж.* — 1. сайланган; *единогласно избранный* — бертавыштан сайланган; 2. сайланма, сайлап алынган; *избранные стихи* — сайланма шигырьләр.

**ИЗБРА'ТЬ** *сов.* — 1. сайлау; *избрать президиум* — президиум сайлау; 2. сайлап алу; *избрать себе профессию* — профессия сайлап алу.

**ИЗБРОДИ'ТЬ** *сов. разг.* — күп җирләрдә булу, күп җирләрне йөреп чыгу.

**ИЗБРОДЯ'ЖНИЧАТЬСЯ** *сов. разг.* — сукбайлыкка күнегү; чын сукбай булып җитү.

**ИЗБРЮЗЖА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — мыгырдыкка әверелү, мыгырдыкка әверелеп бетү.

**И'ЗБУРА** *нареч.* — көрәнсу-...; *избура-жёлтый* — көрәнсу-сары; *избура-красный* — көрәнсу-кызыл.

**ИЗБУ'ШКА** *ж.* — кечкенә өй.

**ИЗБЫВА'ТЬ** *несов. книж. устар. нар.-поэт.* — к. избыть.

**ИЗБЫВА'ТЬСЯ** *несов. книж. устар. нар.-поэт.* — 1. к. избыться; 2. *страд.* коткарылу, арындырылу.

**ИЗБЫ'ТОК** *м. книж.* — 1. артык, калдык, кирәгеннән артканы; 2. күплек, муллык.

**ИЗБЫ'ТОЧНЫЙ** — 1. күп, мул; *избыточный урожай* — мул уңыш; 2. кирәгеннән артык, артык.

**ИЗБЫ'ТЬ** *сов. книж. устар. нар.-поэт.* — котылу, арыну.

**ИЗБЫ'ТЬСЯ** *сов. книж. устар. нар.-поэт.* — бетү, юкка чыгу, гамәлдән чыгу.

**ИЗВА'ЖНИЧАТЬСЯ** *сов. простореч. фам.* — эреләнеп китү, әллә кем булу, әллә кем булып китү; *так изважничался, что и зайти не хочет* — шулкадәр эреләнеп киткән, керергә дә теләми.

**ИЗВАЛЯ'ТЬ** *сов. простореч.* — аунатып пычратып бетерү; *ребёнок извалял всю шапку в грязи* — бала бүреген пычракта аунатып пычратып бетергән.

**ИЗВАЛЯ'ТЬСЯ** *несов. простореч.* — аунап пычранып бетү.

**ИЗВАЯ'НИЕ** *ср. книж. устар.* — сын, статуя.

**ИЗВАЯ'ТЬ** *сов.* — юнып ясау, кырып ясау, чокып ясау, әвәләп ясау (сынлы сурәтне).

**ИЗВЕ'ДАТЬ** *сов. устар.* — 1. кичерү, тату, татып белү; *изведать горе* — кайгы кичерү; 2. *(понять, постичь)* аңлау, төшенү.

**ИЗВЕ'ДЫВАТЬ** *несов. книж. устар.* — к. изведать.

**ИЗВЕ'КА** *нареч. книж. устар.* — борын-борыннан, борын заманнан бирле, элек-электән.

**И'ЗВЕРГ** *м.* — явыз, кансыз, ерткыч; *фашистские изверги* — фашист ерткычлар, фашист явызлар.

**ИЗВЕРГА'ТЬ** *несов.* — 1. ыргыту, атып чыгару; *вулкан извергает лаву и пепел* — вулкан лава белән көл атып чыгара; 2. *перен. (выкрикивать)* кычкырыну, бакырыну, әшәке сүзләр яудыру; 3. *устар.* куу, сөрү, куып чыгару, сөреп чыгару.

**ИЗВЕРГА'ТЬСЯ** *несов.* — атылып чыгу, ургылып чыгу, ыргытылу; *лава начинает извергаться из вулкана* — вулканнан лава атылып чыга башлый.

**ИЗВЕ'РГНУТЬ** *сов. книж.* — к. извергать.

**ИЗВЕ'РГНУТЬСЯ** *сов. книж.* — к. извергаться.

**ИЗВЕРЖЕ'НИЕ** *ср.* — 1. *(действие)* к. извергать, извергаться; 2. *(деятельность вулкана)* ату, ташып чыгу; *извержение Везувия* — Везувийның ташып чыгуы; 3. *только мн. устар. (кал, испражнения, рвота)* тизәк, косык.

**ИЗВЕ'РИВАТЬСЯ** *несов.* — к. извериться

**ИЗВЕ'РИТЬСЯ** *сов.* — ышаныч бетү, ышанмый башлау, ышанычны югалту; *друзья изверились во мне* — дуслар миңа ышанмый башладылар; дусларның миңа ышанычы бетте.

**ИЗВЕРНУ'ТЬСЯ** *сов.* — оста ычкыну, оста ычкынып чыгу, оста котылу, котылып чыгу; *извернуться при ответе* — оста җавап биреп котылу (оста җавап биреп уңайсыз хәлдән котылу).

**ИЗВЕРТЕ'ТЬ** *сов. разг.* — боргалап бозу, боргалап бозып бетерү.

**ИЗВЕРТЕ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. бора-бора бозылып бетү, бора-бора бозылу; *старый винт извертелся совсем* — иске шөреп бора-бора бозылып беткән; 2. *перен. фам.* җилбәзәкләнү, йөгәнсезләнү, тәртипсезләнү; *она совсем извертелась* — ул бөтенләй җилбәзәкләнгән.

**ИЗВЁРТКА** *ж.* — хәйлә, койрык болгау; *все извёртки его известны* — аның бөтен хәйләләре дә билгеле.

**ИЗВЁРТЛИВЫЙ** *обл.* — үткен, тапкыр, булдыклы (нинди генә читен хәлдә калганда да җиңел ерып чыга ала торган).

**ИЗВЁРТЫВАТЬ** *несов. разг.* — к. извертеть.

**ИЗВЁРТЫВАТЬСЯ** I *несов.* — к. изворачиваться.

**ИЗВЁРТЫВАТЬСЯ** II *несов.* — к. извертеться.

**ИЗВЕСТИ'** *сов. простореч.* — 1. тоту, тотып бетерү; *все деньги извела* — барлык акчамны тотып бетердем; 2. *(истребить, уничтожить)* кыру, кырып бетерү, корыту, корытып бетерү; 3. *(лишить сил)* хәлдән тайдыру, хәлдән тайдырып бетерү, аяктан егу; 4. *(расстроить, измучить)* борчу, борчып бетерү, интектерү, интектереп бетерү, теңкәгә тию, теңкәгә тиеп бетү.

**ИЗВЕ'СТИЕ** *ср.* — 1. хәбәр; *последние известия* — соңгы хәбәрләр; 2. мәгълүмат; *первые известия о варягах относятся к 8—9 векам* — варяглар турындагы беренче мәгълүматлар 8—9 гасырларга туры килә; 3. *только мн.* хәбәрләр; *Известия Академии Наук* — Фәннәр Академиясе хәбәрләре.

**ИЗВЕСТИ'СЬ** *сов.* — к. изводиться.

**ИЗВЕСТИ'ТЬ** *сов.* — хәбәр итү, белдерү; *он никого не известил о своем приезде* — үзенең кайтуы турында ул беркемгә дә белдермәгән.

**ИЗВЕСТИ'ТЬСЯ** *сов. устар.* — белү, хәбәр алу.

**ИЗВЁСТКА** *ж.* — к. известь.

**ИЗВЕСТКОВА'ТЬ** *сов.* и *несов. с.-х.* — известь белән ашлау (җирне).

**ИЗВЕСТКО'ВЫЙ** — известьлы; *известковая вода* — известьлы су.

**ИЗВЕ'СТНО** — 1. *в знач. сказ.* билгеле, мәгълүм; *об этом происшествии стало известно из газет* — бу вакыйга турында газеталардан мәгълүм булды; 2. *ввод. сл.* әлбәттә, билгеле; *известно, с ним не сговоришься* — әлбәттә, аның белән килешә алмассың.

**ИЗВЕ'СТНОСТЬ** *ж.* — 1. *только ед.* билгелелек, билгеле булу; 2. дан, шөһрәт; *приобрёл известность своими выступлениями* — үзенең чыгышлары белән дан казанды; 3. *(известный человек)* танылган кеше, дан казанган кеше. ◇ **Привести в известность** — аныклау, ачыклау. **Поставить в известность** — белдерү, хәбәр итү.

**ИЗВЕ'СТНЫЙ** — 1. билгеле, таныш, һәркемгә мәгълүм; *известное всем событие* — һәркемгә билгеле вакыйга; 2. атаклы, данлыклы, танылган, мәшһүр; *известный художник* — атаклы художник; 3. кайбер, билгеле бер; *при известных условиях* — кайбер шартларда, билгеле бер шартларда.

**ИЗВЕСТНЯ'К** *м.* — известняк (известь катнашкан тау токымы, мәсәлән, мәрмәр, гипс, акбур).

**ИЗВЕСТНЯКО'ВЫЙ** — известняк...-ы; *известняковые породы* — известняк токымнары.

**И'ЗВЕСТЬ** *ж. мн.* нет — известь; *гашёная известь* — сүндерелгән известь.

**ИЗВЕ'СТЬ** *сов.* — к. извести.

**ИЗВЕ'Т** *м. устар. книж.* — әләк, донос, яла.

**ИЗВЕ'ТРЕННИЧАТЬСЯ** *сов. разг. фам.* — җилбәзәкләнү, җилкуарга әйләнү.

**ИЗВЕ'ТЧИК** *м. книж. устар.* — әләкче, доносчы, яла ягучы.

**ИЗВЕТША'ЛЫЙ** *книж. устар.* — искергән, искереп беткән, тузып беткән; *изветшалое здание* — искергән бина.

**ИЗВЕТША'ТЬ** *сов. книж. устар.* — искерү, тузып бетү, яраксыз хәлгә килү.

**ИЗВЕ'ЧНЫЙ** *книж. устар.* — борынгы, борынгы заманнардан килә торган, бик иске, бик күптәнге.

**ИЗВЕЩА'ТЬ** *несов.* — к. известить.

**ИЗВЕЩА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — белдерелү, хәбәр ителү.

**ИЗВЕЩЕ'НИЕ** *ср.* — 1. *(сообщение)* хәбәр, белдерү; 2. *(документ)* белдерү кәгазе, хәбәр итү кәгазе, повестка.

**ИЗВЕ'ЯТЬ** *сов.* — җилгәреп бетерү.

**ИЗВИ'В** *м.* — борылма, борылыш.

**ИЗВИВА'ТЬ** *несов.* — к. извить.

**ИЗВИВА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. боргалану; *змея извивалась всем телом, стараясь вырваться* — елан, ычкынырга тырышып, бөтен гәүдәсе белән боргалана иде; 2. *книж. (иметь непрямое, извилистое направление) (о реке)* бормалана-бормалана агу, борылып-борылып агу, бормаланып агу; *(о дороге)* бормалана-бормалана бару; 3. *перен. разг. устар. (униженно добиваться)* ялагайлану, ярарга тырышу; 4. *перен. разг. фам. презрит. (хитря, уклоняться)* койрык болгау.

**ИЗВИ'ВИСТЫЙ** — к. извилистый.

**ИЗВИ'ЛИНА** *ж.* — 1. *(волнистое искривление, изгиб)* — борылма, борма; *извилина дороги* — юл борылмасы; 2. җыерчык; *извилины мозга* — ми җыерчыклары.

**ИЗВИ'ЛИСТЫЙ** — борылмалы, бормалы, боргаланган; *извилистая речка* — борылмалы елга; *извилистые улицы* — боргаланган урамнар.

**ИЗВИНЕ'НИЕ** *ср.* — 1. гафу итү, кичерү; *прошу извинения за беспокойство* — борчуым өчен гафу итүегезне үтенәм; 2. *книж.* гафу итәргә сәбәп, кичерергә сәбәп, гафу итәргә нигез, кичерү өчен нигез; *болезнь служит ему извинением* — авыруы аркасында (авыру булуы сәбәпле) аны гафу итәргә кирәк; 3. гафу үтенү; *он не хотел принимать моих извинений* — ул минем гафу үтенүләремне кабул итәргә теләмәде.

**ИЗВИНИ', ИЗВИНИ'ТЕ** *пов. накл.* — 1. гафу ит, гафу итегез; 2. *разг.* юк инде; *извините, это не так* — юк инде, бу алай түгел.

**ИЗВИНИ'ТЕЛЬНЫЙ** — 1. гафу ителерлек, кичерерлек, акларлык; *в его годы желание это весьма извинительное* — аның яшендә бу теләк һичшиксез гафу ителерлек; 2. *устар.* гафу үтенгән, кичерүне сораган, гафу үтенеп язылган (әйтелгән), кичерүне сорап язылган (әйтелгән); *извинительное письмо* — кичерүне сорап язылган хат.

**ИЗВИНИ'ТЬ** *сов.* — 1. гафу итү, кичерү; *прошу извинить меня за беспокойство* — борчуым өчен мине гафу итүегезне үтенәм; 2. *книж.* аклау; *извинить проступок молодостью* — гаепне (кимчелекне) яшьлек сәбәпле эшләнгән дип аклау.

**ИЗВИНИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. гафу үтенү, кичерүне сорау, аклауны сорау; *извинился перед другом* — дустым каршында гафу үтендем; 2. *книж. устар.* сәбәп итеп кую; *он извинился своей болезнью и не пришёл* — ул үзенең авыруын сәбәп итеп куйды һәм килмәде.

**ИЗВИНТИ'ТЬ** *сов. простореч.* — 1. *(винтя, испортить)* бора-бора туздырып бетерү, бора-бора шомартып бетерү (винт сырын); 2. *(винтя, сделать много дыр)* бораулап тишеп бетерү.

**ИЗВИНТИ'ТЬСЯ** *сов. простореч.* — шомарып бетү (винт сыры турында).

**ИЗВИ'НЧИВАТЬ** *несов. простореч.* — к. извинтить.

**ИЗВИ'НЧИВАТЬСЯ** *несов. простореч.* — к. извинтиться.

**ИЗВИНЯ'ТЬ** *несов.* — к. извинить.

**ИЗВИНЯ'ТЬСЯ** *несов.* — к. извиниться.

**ИЗВИ'ТЬ** *сов.* — 1. бөгәрләү; *змея извила хвост кольцом* — елан койрыгын боҗра кебек итеп бөгәрләгән; 2. *(истратить на витьё)* ишүгә тотып бетерү.

**ИЗВИ'ТЬСЯ** *сов.* — бөгәрләнү.

**ИЗВЛЕКА'ТЬ** *несов.* — к. извлечь.

**ИЗВЛЕКА'ТЬСЯ** *несов. книж.* — 1. к. извлечься; 2. *страд.* тартып чыгарылу, суырып алыну; чыгарылу, алыну; сайлап алыну.

**ИЗВЛЕЧЕ'НИЕ** *ср. книж.* — 1. *только ед.* чыгару, тартып чыгару, алу; *извлечение осколков из раны* — ярадан снаряд кыйпылчыкларын алу; 2. *(выдержка, выписка из сочинения, документа)* чыгарма, өземтә. ◇ Извлечение корня *мат.* — тамыр алу.

**ИЗВЛЕ'ЧЬ** *сов. книж.* — 1. тартып чыгару, суырып алу; *извлечь меч из ножен* — кылычны кынысыннан тартып чыгару; 2. *перен.* чыгару, алып чыгу; *извлечь народ из мрака невежества* — халыкны наданлык караңгылыгыннан чыгару; 3. алу, чыгару, табу; *извлечь сок из растений* — үсемлекләрдән сок алу (чыгару); 4. *перен.* сайлап алу, табу; *извлечь нужные цитаты из классиков* — классиклардан кирәкле цитаталарны сайлап алу. ◇ Извлечь корень *мат.* — тамыр алу.

**ИЗВЛЕ'ЧЬСЯ** *сов. книж.* — чыгарылу, суырып чыгарылу, суырып алыну; *пуля легко извлеклась из раны* — пуля ярадан җиңел чыгарылды.

**ИЗВНЕ'** *нареч. книж.* — тыштан, тышкы яктан, читтән; *помощь извне* — читтән ярдәм.

**ИЗВОДИ'ТЬ** *несов.* — 1. *разг. (тратить, расходовать)* тотү; 2. кыру, бетерү, корыту; *изводить леса* — урманнарны корыту; 3. *разг.* хәлдән тайдыру, аяктан егу; *изводит меня это горе* — бу кайгы мине аяктан ега; 4. *кого-что разг. (раздражать, расстраивать, мучить)* борчу, теңкәгә (теңкәсенә) тию, интектерү, йөдәтү.

**ИЗВОДИ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. *разг. (терзаясь чем-н., терять силы)* (борчылып) хәлдән таю, интегү, аяктан егылу, йөдәү; *изводиться от зависти* — көнләшүдән интегү; *изводиться от болезней* — авырулардан йөдәү; 2. *простореч. (тратить, истощать свои средства, деньги)* тотып бете-

рү, таратып бетерү, туздыру, әрәм итү; 3. *страд.* тотылу; бетерелү, корытылу; хәлдән тайдырылу.

**ИЗВО'З** *м. мн.* нет, *дореволю.* — олаучылык, йөк йөртү; *заниматься извозом* — олаучылык белән шөгыльләнү.

**ИЗВОЗИ'ТЬ** *сов. простореч.* — (арлыбирле йөртеп) пычратып бетерү, таушалдырып бетерү.

**ИЗВОЗИ'ТЬСЯ** *сов. простореч.* — (арлыбирле йөреп) буялып бетү, пычранып бетү.

**ИЗВО'ЗНИЧАТЬ** *несов. простореч.* — олаучылык итү, олаучы булып эшләү, извозчик булып эшләү, йөк ташу белән шөгыльләнү.

**ИЗВО'ЗНЫЙ** — олаучылык...-ы; *извозный промысел* — олаучылык кәсебе.

**ИЗВОЗОВЛАДЕ'ЛЕЦ** *м. офиц. устар.* — олаучылык предприятиесе хуҗасы.

**ИЗВО'ЗЧИК** *м.* — 1. олаучы, йөк ташучы, извозчик; 2. *разг.* извозчик (экипаж һәм аның кучеры); *сели на извозчика* — извозчикка утырдык.

**ИЗВО'ЗЧИЧИЙ** — извозчик...-ы; *извозчичья пролётка* — извозчик тарантасы.

**ИЗВОЛЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж. устар.* — боерык, теләк; *по барскому изволению* — барин боерыгы буенча (боерыгы белән).

**ИЗВО'ЛИТЬ** *несов.* — теләү,... -сы килү; *не изволишь ли покушать?* — ашап алырга теләмисеңме? ашыйсың килмиме? ◇ Изволь, извольте *пов. накл.* — 1. *разг.* ярый; яхшы, синеңчә (сезнеңчә) булсын; *извольте, останусь ещё на часок* — ярый, тагын бер сәгатькә калам; 2. рәхим ит(егез), ал(ыгыз), мә(гез); *дайте мне книгу.* — *Извольте* — миңа китап бирегезче. — Рәхим итегез; 3. *(для выражения беспрекословного приказания)* рәхим итеп; *извольте выйти!* — рәхим итеп чыгып китегез!

**ИЗВОЛНОВА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — нык дулкынлану, интегеп бетү, борчылып бетү; *мать изволновалась, не получая известий* — хәбәр алмаганлыктан, ана борчылып бетте.

**ИЗВОЛО'К** *м. обл.* — сөзәк калкулык.

**ИЗВОЛОЧИ'ТЬ** *сов. простореч.* — сөйрәп пычратып (бозып) бетерү, сөйрәп таушалдырып бетерү.

**ИЗВО'ЛЬНИЧАТЬСЯ** *сов. простореч.* — үзсүзләләнеп бетү, бозылып бетү, әхлаксызланып бетү.

**ИЗВОРА'ЧИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — к. извернуться.

**ИЗВОРОВА'ТЬСЯ** *сов. простореч.* — төзәлмәслек каракка әйләнү, караклыкка бирелү.

**ИЗВОРО'Т** *м. устар.* — 1. борылыш, борылма; *извороты реки* — елганың борылмалары; 2. *(уловка, хитрость)* хәйлә.

**ИЗВОРО'ТИСТЫЙ** *простореч.* — к. изворотливый.

**ИЗВОРО'ТЛИВОСТЬ** *ж. мн.* нет — чаялык, тапкырлык, осталык.

**ИЗВОРО'ТЛИВЫЙ** — 1. тапкыр; *изворотливый человек* — тапкыр кеше; 2. *(увёртливый)* елгыр, житез; *изворотливое животное* — елгыр хайван.

**ИЗВОРЧА'ТЬСЯ** *сов. простореч. фам.* — мыгырдыкка әйләнү, туктаусыз мыгырдау, туктаусыз сукрану.

**ИЗВРАТИ'ТЬ** *сов. книж.* — 1. бозу; *плохое воспитание извратило его ум и сердце* — начар тәрбия аның акын һәм күңелен бозган; 2. бозып аңлату; *извратить смысл слов* — сүзләрнең мәгънәсен бозып аңлату.

**ИЗВРАТИ'ТЬСЯ** *сов. книж.* — 1. *устар. (испортиться, стать извращенным)* бозылу, әхлаксызлану, азу; 2. *(о мыслях, словах)* бозып аңлатылу.

**ИЗВРАЩА'ТЬ** *несов. книж.* — к. извратить.

**ИЗВРАЩА'ТЬСЯ** *несов. книж.* — к. извратиться.

**ИЗВРАЩЕ'НИЕ** *ср. книж.* — 1. *(действие)* к. извращать; 2. азгынлык, бозыклык; *нравственное извращение* — әхлакый бозыклык.

**ИЗВРАЩЁННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — азгынлык, бозыклык, әхлаксызлык, бозылганлык.

**ИЗВЯЗА'ТЬ** *сов. разг.* — бәйләүгә тотып бетерү (мәсәлән, җепне, йонны).

**ИЗВЯ'ЗЫВАТЬ** *несов. разг.* — к. извязать.

**ИЗВЯ'ЗЫВАТЬСЯ** *несов. страд. разг.* — бәйләүгә тотылып бетү (җеп, йон турында).

**ИЗГА'ДИТЬ** *сов. простореч.* — 1. *(испачкать, загрязнить)* буяп бетерү, пычратып бетерү, шакшылап бетерү; 2. *перен. вульг.* бозу, бозып бетерү; *портной изгадил пальто* — тегүче пальтоны бозган.

**ИЗГА'ДИТЬСЯ** *сов. простореч.* — бозылу; *погода к вечеру изгадилась* — һава кичкә таба бозылды.

**ИЗГА'ЖИВАТЬ** *несов. простореч.* — к. изгадить.

**ИЗГА'ЖИВАТЬСЯ** *несов. простореч.* — к. изгадиться.

**ИЗГА'РИНА** *ж. обл. спец.* — көек, көйгән әйбер, янык, янган әйбер.

**ИЗГИ'Б** *м.* — 1. борылыш, бөгелеш; *на изгибе реки* — елга борылышында; 2. *перен. книж. чаще мн.* үткенлек, нечкәлек, иң нечкә төсмер; *изгибы голоса* — тавышның иң нечкә төсмерләре; *изгибы мыслей* — фикер нечкәлекләре.

**ИЗГИБА'ТЬ** *несов.* — 1. бөгү, ию, сыгу; *изгибать шею* — муенны бөгү; 2. кыйшайту; *изгибать губы* — иреннәрне кыйшайту.

**ИЗГИБА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. бөгелү, сыгылу; *гвоздь изгибается* — кадак бөгелә; 2. кыйшаю; *её губы страдальчески изгибались* — газапланудан аның иреннәре кыйшаялар иде.

**ИЗГИ'БИНА** *ж. обл.* — борылыш, борылма; *изгибины реки удлиняли расстояние* — елганың борылышлары араны озынайталар иде.

**ИЗГИ'БИСТЫЙ** *обл.* — борылмалы, күп борылмалы, күп борылышлы, бормалыбормалы; *изгибистая река* — күп борылмалы елга.

**ИЗГЛА'ДИТЬ** *сов.* — 1. *книж.* шомартып бетерү, ашап бетерү; *время изгладило надпись на камне* — вакыт таштагы язма-

ны ашап бетергән (күп вакыт үтү белән таштагы язма ашалып беткән); 2. *перен. книж.*— бетерү, беленмәслек итү, оныттыру; *изгладить неприятное впечатление* — күңелдәге начар тәэсирне бетерү; *время изгладит из памяти давние события* — вакыт хәтерлә калган күптәнге вакыйгаларны онытгырыр; 3. *просторeч.* үтүкләп бетерү (керне).

**ИЗГЛА'ДИТЬСЯ** *сов. книж.*— 1. ашалып бетү, шомарып бетү, беленмәслек булып калу; *буквы рукописи изгладились от времени* — кулъязманың хәрефләре вакыт үтү белән ашалып беткәннәр; 2. *перен.* югалу, онытылу, юкка чыгу; *в памяти ещё не изгладились ужасы второй мировой войны* — икенче бөтендөнья сугышының дәһшәтләре онытылмаганнар әле (хәтердә әле).

**ИЗГЛА'ДЫВАТЬ** *несов. просторeч.* — к. изглодать.

**ИЗГЛА'ДЫВАТЬСЯ** *просторeч. страд.*— кимерелү, кимереп бетерелү.

**ИЗГЛА'ЖИВАТЬ** *несов.*— к. изгладить.

**ИЗГЛА'ЖИВАТЬСЯ** *несов.* — к. изгладиться.

**ИЗГЛОДА'ТЬ** *сов. просторeч. разг.*— кимереп бетерү, кимергәләп бетерү.

**ИЗГНА'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.*—1. *(действие)* к. изгнать; 2. сөрген; *жить в изгнании* — сөргендә яшәү.

**ИЗГНА'ННИК** *м.*, **ИЗГНА'ННИЦА** *ж. книж.*— сөрелгән кеше, куылган кеше, сөргенгә җибәрелгән кеше, сөреп чыгарылган кеше, сөргендәге кеше.

**ИЗГНА'ННИЧЕСКИЙ** *книж.*— сөрелгән кеше...-ы; сөргендәге кеше...-ы; *изгнанническая жизнь* — сөргендәге кеше тормышы.

**ИЗГНА'ННИЧЕСТВО** *ср. мн.* нет, *книж. устар.*— сөргендә булу, сөргендә тору, сөргендә яшәү.

**ИЗГНА'ТЬ** *сов. книж.*— 1. *(выгнать)* куу, куып чыгару, сөрү, сөреп чыгару, сөреп җибәрү; 2. *перен.* тамырын корыту, тамырыннан йолкып алу, юкка чыгару, бетерү, ...-дан чыгару; *изгнать из употребления алкоголь* — алкоголь куллануны бетерү. ◇ **Изгнать плод** *мед.*— аборт ясау, бала төшерү.

**ИЗГНИВА'ТЬ** *несов.*— к. изгнить.

**ИЗГНИ'ТЬ** *сов.*— черү, череп бетү.

**ИЗГО'Й** *м. истор.*— изгой (борынгы Русьта — үз сословиесеннән, сыйныфыннан төшеп калган кеше).

**ИЗГОЛО'ВОК** *м. обл.*— к. изголовье.

**ИЗГОЛО'ВЬЕ** *ср.*— баш очы; *стоять у изголовья* — баш очында басып тору. ◇ **Изголовьем служило ему седло** — ияр аңа мендәр булып хезмәт итә иде.

**ИЗГОЛОДА'ТЬСЯ** *сов.*— 1. ачыгып бетү; ачыгып ябыгып бетү; 2. *перен. разг.* сусау, сагыну; *изголодался по хорошей музыке* — яхшы музыкага сусадым, яхшы музыканы сагындым.

**ИЗГОНЯ'ТЬ** *несов. книж.*— к. изгнать.

**ИЗГОНЯ'ТЬСЯ** *несов. страд. книж.* — 1. куылу, куып чыгарылу; 2. тамыры корытылу, юкка чыгарылу.

**ИЗГОРА'ТЬ** *несов. книж. устар.*— к. изгореть.

**ИЗГОРБИ'ТЬ** *сов. обл.*— бөкрәйтү; *изгорбить спину* — арканы бөкрәйтү.

**ИЗГОРБИ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— 1. *(согнуть спину)* бөкрәю, арканы бөкрәйтү; 2. калҗаю, калҗаеп бетү; *картон весь изгорбился* — катыргы бөтенләй калҗаеп беткән.

**ИЗГОРЕ'ТЬ** *сов. книж. устар.*— янып бетү; *за месяц изгорело 10 литров керосина* — ай буена 10 литр керосин янып бетте.

**ИЗГОРО'ДКА** *ж. разг.*— тәбәнәк читән, тәбәнәк киртә.

**И'ЗГОРОДЬ** *ж.*— киртә, читән.

**ИЗГОТА'ВЛИВАТЬ** *несов. разг.*— к. изготовлять.

**ИЗГОТА'ВЛИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — к. изготовляться.

**ИЗГОТОВИ'ТЕЛЬ** *м. книж. редко.* — хәзерләүче (кеше), эшләп чыгаручы (кеше).

**ИЗГОТО'ВИТЬ** *сов.*— 1. *книж. (выработать)* эшләп чыгару; 2. *устар. (приготовить)* хәзерләү, хәзерләп кую; 3. *просторeч. (о пище)* хәзерләү, пешерү.

**ИЗГОТО'ВИТЬСЯ** *сов.*— хәзерләнү.

**ИЗГОТОВЛЯ'ТЬ** *несов.*— к. изготовить.

**ИЗГОТОВЛЯ'ТЬСЯ** *несов.*— к. изготовиться.

**ИЗГРАФИ'ТЬ** *сов. спец.*— графалау, графалап чыгу, сызып чыгу (кәгазьне).

**ИЗГРАФЛЯ'ТЬ** *несов. спец.*— к. изграфить.

**ИЗГРАФЛЯ'ТЬСЯ** *несов. страд. спец.*— графалану, сызылу.

**ИЗГРЫЗА'ТЬ** *несов.*— к. изгрызть.

**ИЗГРЫЗА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— кимерелеп бетү.

**ИЗГРЫ'ЗТЬ** *сов.*— 1. кимереп бетерү; *мыши изгрызли деревянную посуду* — тычканнар агач савытны кимереп бетергән; 2. *разг.* чәйнәп бетерү.

**ИЗГРЯЗНИ'ТЬ** *сов. разг.*— пычратып бетерү, буяп бетерү, шакшылап бетерү.

**ИЗГРЯЗНИ'ТЬСЯ** *сов. разг* — пычранып бетү, буялып бетү, шакшыланып бетү.

**ИЗГРЯЗНЯ'ТЬ** *несов. разг.*— к. изгрязнить.

**ИЗГРЯЗНЯ'ТЬСЯ** *несов. разг.*— к. изгрязниться.

**ИЗГУБИ'ТЬ** *сов. книж. устар. обл.*— һәлак итү, харап итү.

**ИЗГУБЛЯ'ТЬ** *несов. книж. устар. обл.*— к. изгубить.

**ИЗДАВА'ТЬ** *несов. книж.*— к. издать.

**ИЗДАВА'ТЬСЯ** *несов. книж.*— 1. к. издаться; 2. *страд.* чыгарылу, бастырып чыгарылу.

**И'ЗДАВНА'** *нареч. книж.*— күптәннән, әлек-әлектән, борынгыдан, борын-борыннан, әллә кайчаннан, бик күптәннән; *русское население издавна живёт на Белом море* — рус халкы Ак диңгез буенда әлек-әлектән яши.

**ИЗДА'ИВАТЬ** *несов. спец.*— к. издоить.

**ИЗДА'ИВАТЬСЯ** *несов. спец.*— к. издоиться.

**ИЗДА'ЛБЛИВАТЬ** *несов. разг.*— к. издолбить.

**ИЗДА'ЛБЛИВАТЬСЯ** *несов. страд. разг.*— чокылып тишелеп бетү, чокырайтып бетерелү.

**ИЗДАЛЕКА', ИЗДАЛЁКА** *нареч.* — 1. ерактан, ерак җирдән; *я ещё издалека увидел его* — мин аны ерактан ук күрдем; 2. *разг.* читләтеп; *старался говорить издалека* — читләтеп сөйләргә тырышты.

**ИЗДАЛЕ'ЧА, ИЗДАЛЕ'ЧЕ** *нареч. обл.*— к. издалека.

**И'ЗДАЛИ** *нареч.*— к. издалека 1.

**ИЗДА'НИЕ** *ср.*— 1. *(действие)* басып чыгару, бастырып чыгару; *издание учебников* — дәреслекләр басып чыгару; 2. басма; *первое издание* — беренче басма; *сокращённое издание* — кыскартылган басма.

**ИЗДА'ТЕЛЬ** *м.*, **ИЗДА'ТЕЛЬНИЦА** *ж.*— бастырып чыгаручы, издатель.

**ИЗДА'ТЕЛЬСКИЙ** *книж.*— китаплар бастыру...-ы; *издательское дело* — китаплар бастыру эше; *издательский план* — китаплар бастыру планы.

**ИЗДА'ТЕЛЬСТВО** *ср.*— 1. издательство (китап, газета һ. б. бастырып чыгару учреждениесе); *государственное издательство* — дәүләт издательствосы; 2. *книж. устар.* к. издание 1.

**ИЗДА'ТЬ** *сов. книж.*— 1. бастырып чыгару; *издать книги* — китаплар бастырып чыгару; 2. чыгару; *издать закон* — закон чыгару. ◇ **Издать звук** — аваз иштерү, тавыш иштерү, кычкырып аваз бирү.

**ИЗДА'ТЬСЯ** *сов. книж.*— басылу, басылып чыгу.

**ИЗДЕВА'ТЕЛЬСКИЙ** — мәсхәрәле; мыскыллаулы; *издевательское отношение* — мәсхәрәле мөнәсәбәт.

**ИЗДЕВА'ТЕЛЬСТВО** *ср.* —1. *только ед. (действие)* көлү, мыскыллау, хурлау; 2. мәсхәрә, мыскыл, кимсетеп көлү, мәсхәрәләп көлү, ачы көлү; *мне надоели твои издевательства* — синең кимсетеп көлүләрең мине туйдырды.

**ИЗДЕВА'ТЬСЯ** *несов.*— ачы көлү, мыскыл итү, мыскыллау, мәсхәрә итү, хурлау, мәсхәрәләп көлү.

**ИЗДЕ'ВКА** и **ИЗДЁВКА** *ж. простореч.*— к. издевательство.

**ИЗДЕ'ЛИЕ** *ср.*— 1. *только ед. (выделка, производство)* эшләп чыгару; 2. әйбер, товар; *трикотажные изделия* — трикотаж әйберләр; *деревянные изделия* — агач әйберләр; 3. *истор.* к. барщина.

**ИЗДЁРГАННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— таушалганлык, какшаганлык, эштән чыкканлык; *издёрганность нервов* — нервларның какшаганлыгы.

**ИЗДЁРГАТЬ** *сов. разг.*— 1. йолыккалап бетерү, йолыккалап эштән чыгару, йолыккалап туздырып бетерү; *дети издёргали всю бахрому у скатерти* — балалар ашъяулыкның чукларын йолыккалап бетергәннәр; 2. *перен. фам. (привести чем-н. в нервное состояние)* йончытып бетерү, интектереп бетерү, җәфалап бетерү.

**ИЗДЁРГАТЬСЯ** *сов. разг.*— 1. *(истрепаться от дергания)* йолыккалаудан тузып бетү, йолыккалаудан бозылып бетү; 2. *перен. фам.* йончып бетү, интегеп бетү, җәфаланып бетү, эштән чыгу; *за последний год он совсем издёргался* — соңгы елда ул бөтенләй эштән чыкты.

**ИЗДЁРГИВАТЬ** *несов. разг.*— к. издёргать.

**ИЗДЁРГИВАТЬСЯ** *несов. разг.*— к. издёргаться.

**ИЗДЕРЖА'ТЬ** *сов.*— тотып бетерү, таратып бетерү; *издержать все деньги* — бөтен акчаны тотып бетерү.

**ИЗДЕРЖА'ТЬСЯ** *сов. разг.*— 1. күп акча тотү; *я в дороге издержался* — юлда мин күп акча тоттым; 2. тотылып бетү; *все деньги издержались* — бөтен акча тотылып бетте.

**ИЗДЕ'РЖИВАТЬ** *несов.*— к. издержать.

**ИЗДЕ'РЖИВАТЬСЯ** *несов.*— к. издержаться.

**ИЗДЕ'РЖКА** *ж. чаще. мн.*— расход, чыгым; *судебные издержки* — суд расходлары.

**ИЗДЕ'ТСТВА** *нареч. устар.*— балачактан ук, балалык елларыннан бирле.

**ИЗДИРА'ТЬ** *несов. простореч.*— к. изодрать.

**ИЗДИРА'ТЬСЯ** *несов. простореч.*— 1. к. изодраться; 2. *страд.* ертып бетерелү, тишеп бетерелү.

**ИЗДОИ'ТЬ** *сов. спец.*— сөт бирмәс хәлгә җиткерү (сыерны, кәҗәне, сава белми савып).

**ИЗДОИ'ТЬСЯ** *сов. спец.*— сөт бирүдән туктау, сөт ташлау, ташлану; *корова уже издоилась* — сыер сөт бирүдән туктады инде.

**ИЗДОЛБИ'ТЬ** *сов. разг.*— чокырайтып бетерү, чокып тишеп бетерү; *капли издолбили камень* — тамчылар ташны чокырайтып бетергәннәр.

**ИЗДО'ЛЬЩИНА** *ж. мн.* нет, *истор. экон.*— уртакка эшләү, өлешкә эшләү (элекке вакытта уңышның билгеле бер өлешен түләү шарты белән җирне арендага алу формасы).

**ИЗДО'ХНУТЬ** *сов.*— 1. *(о животных)* үлү; *собака издохла* — эт үлде; 2. *разг. (о человеке — с оскорбительным оттенком)* дөмегү, тончыгу.

**ИЗДРЕ'ВЛЕ** *нареч. книж. устар.*— элек-электән, борынгыдан ук, борын-борыннан.

**ИЗДРОБИ'ТЬ** *сов. спец.*— ваклау, ваклап бетерү; *издробить камень* — ташны ваклау.

**ИЗДРО'ГНУТЬ** *сов. разг.*— туңып бетү, күшегеп бетү.

**ИЗДЫРЯ'ВЕТЬ** *сов. простореч.*— тишелеп бетү, тишкәләнеп бетү.

**ИЗДЫРЯ'ВИТЬ** *сов. разг.*— тишеп бетерү, тишкәләп бетерү.

**ИЗДЫРЯ'ВИТЬСЯ** *сов. разг.*— тузып бетү, тишелеп чыгу, тишелеп бетү, тишкәләнеп бетү.

**ИЗДЫРЯ'ВЛИВАТЬ** *несов. простореч.*— к. издырявить.

**ИЗДЫРЯ'ВЛИВАТЬСЯ** *несов. просто-*

*реч.* — 1. к. издырявиться; 2. *страд.* туздырып бетерелү, тишкәләп бетерелү.

**ИЗДЫХА'НИЕ** *ср. книж. устар.* — үлү. ◇ **При последнем издыхании** *книж.* — соңгы сулышын алганда. **До последнего издыхания** *книж.* — үлгәнгә кадәр, соңгы сулышка кадәр.

**ИЗДЫХА'ТЬ** *несов.* — к. издохнуть.

**ИЗЖА'ЛИВАТЬ** *несов.* — к. изжалить.

**ИЗЖА'ЛИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — чагылып бетү (корт, елан тарафыннан).

**ИЗЖА'ЛИТЬ** *сов.* — чагып бетерү; *пчёлы изжалили мне всю шею и руки* — бал кортлары минем бөтен муенымны һәм кулларымны чагып бетерделәр.

**ИЗЖА'РИТЬ** *сов.* — 1. кыздыру, кыздырып алу, куырып алу, кыздырып пешерү; *изжарить курицу* — тавыкны кыздыру; 2. *разг. фам.* пешерү, пешереп бетерү; *солнце изжарило голову* — кояш башымны пешереп бетерде.

**ИЗЖА'РИТЬСЯ** *сов.* — 1. *(о пище)* куырылу, куырып пешерелү, кыздырып пешерелү; 2. *разг. фам.* пешеп бетү (эсседән, кызудан).

**ИЗЖЕВА'ТЬ** *сов. разг.* — 1. чәйнәп бозу, чәйнәп эштән чыгару; *телёнок изжевал повешенное на дворе бельё* — бозау ишек алдында эленгән керне чәйнәп эштән чыгарган; 2. *спец.* *(жуя, израсходовать)* чәйнәп бетерү.

**ИЗЖЁВЫВАТЬ** *несов. разг.* — к. изжевать.

**ИЗЖЁВЫВАТЬСЯ** *несов. страд. разг.* — 1. чәйнәп эштән чыгарылу; 2. чәйнәлеп бетү.

**И'ЗЖЕЛТА** *нареч.* — саргылт-...; *изжелта-красный* — саргылт-кызыл.

**ИЗЖЕЛТИ'ТЬ** *сов. разг.* — сарыга ману; сарыга буяу.

**ИЗЖЕ'ЧЬ** *сов. разг.* — 1. *(прожечь во многих местах)* яндырып бетерү, яндырып бозу, яндырып эштән чыгару; 2. *(причинить много ожогов)* пешереп бетерү; 3. *разг. (израсходовать на топку)* яндырып бетерү, ягуга тотып бетерү.

**ИЗЖЕ'ЧЬСЯ** *сов. разг.* — 1. *(причинить себе много ожогов)* пешеп бетү; 2. *(о топливе; израсходоваться)* ягылып бетү, яндырылып бетү, ягуга тотылып бетү. ◇ **Изжёгся о крапиву** — кычыткан чакты.

**ИЗЖИВА'ТЬ** *несов. книж.* — к. изжить.

**ИЗЖИВА'ТЬСЯ** *несов. книж.* — 1. *(искореняться, постепенно исчезать)* юкка чыга бару, югала бару, бетә бару, акрынлап бетү; 2. *страд.* бетерелү.

**ИЗЖИГА'ТЬ** *несов. разг.* — к. изжечь.

**ИЗЖИГА'ТЬСЯ** *несов. разг.* — к. изжечься.

**ИЗЖИ'ТЬ** *сов. книж.* — 1. *(избавиться от чего-н.)* бетерү, арыну; *изжить недостатки* — житешсезлекләрне бетерү; житешсезлекләрдән арыну; 2. *устар.* котылу, арыну, оныту; *изжить печали* — кайгылардан арыну, кайгыларны оныту.

**ИЗЖО'ГА** *ж. мн.* нет — сару кайнау.

**ИЗ-ЗА** *предлог с род. п.* — 1. артыннан, аръягыннан; *приехал из-за моря* — диңгез артыннан (аръягыннан) кайтты; 2. янынннан; *встать из-за стола* — өстәл яныннан торып китү; 3. аркасында, сәбәпле, ... -дан; *разошлись из-за пустяков* — юк-бар сәбәпләр аркасында килешә алмадык; *из-за тебя мы опоздали* — синең аркаңда без соңга калдык; 4. булганлыктан, булганга күрә; *из-за шума ничего не слышно* — тавыш булганлыктан бернәрсә дә ишетелми.

**И'ЗЗЕЛЕНА** *нареч.* — яшькелт-...; *иззелена-жёлтый* — яшькелт-сары.

**ИЗЗЕЛЕНИ'ТЬ** *сов. разг.* — яшелгә буяп бетерү, яшелләндереп бетерү.

**ИЗЗУ'БРИВАТЬ** *несов. разг.* — к. иззубрить.

**ИЗЗУ'БРИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. к. иззубриться I; 2. *страд.* кыршылдырып бетерелү.

**ИЗЗУБРИ'ТЬ** *сов. разг.* — тешәп бетерү, тешләндереп бетерү; кыршылдырып бетерү; *иззубрить нож* — пычакны кыршылдырып бетерү.

**ИЗЗУБРИ'ТЬСЯ** I *сов. разг.* — үтмәсләнеп бетү; кыршылып бетү.

**ИЗЗУБРИ'ТЬСЯ** II *сов. неодобр.* — ятлыйятлый (күңелдән бикли-бикли) алҗып бетү, хәлдән таю.

**ИЗЗЯ'БНУТЬ** *сов. простореч.* — өшеп бетү, туңып бетү, күшегеп бетү.

**ИЗЛА'ВЛИВАТЬ** *несов. простореч.* — к. изловить.

**ИЗЛАГА'ТЬ** *несов. книж.* — к. изложить.

**ИЗЛАГА'ТЬСЯ** *несов. страд. книж.* — бәян ителү, язып (сөйләп) аңлатылу.

**ИЗЛА'ЗАТЬ** *несов.* — к. излазить.

**ИЗЛА'ЗИТЬ** *сов. разг.* — үрмәләп йөреп чыгу, йөрмәгән җирне калдырмау; йөреп чыгу. ◇ **Излазил все углы** — барлык почмакларны актарып чыктым.

**ИЗЛА'МЫВАТЬ** *несов.* — к. изломать.

**ИЗЛА'МЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. изломаться; 2. *страд.* ватып бетерелү, сындырып бетерелү.

**ИЗЛАТА'ТЬ** *сов. обл.* — ямау белән тутыру.

**ИЗЛА'ЯТЬ** *сов. простореч. вульг.* — тиргәп бетерү, сүгеп ташлау.

**ИЗЛЕ'НИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — к. излениться.

**ИЗЛЕНИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — ялкауланып бетү.

**ИЗЛЁТ** *мн.* нет, *м. спец.* — очуның тәмамланып килүе, очканда соңгы пунктка (җиргә төшүгә) якынлашу моменты. ◇ **Пуля на излёте бьёт слабо** — җиргә төшәр алдыннан пуляның көче аз була.

**ИЗЛЕТА'ТЬ** I *несов. книж. устар. поэт.* — чыгу; *из уст его излетали какие-то непонятные слова* — аның авызыннан ниндидер аңлаешсыз сүзләр чыга иде.

**ИЗЛЕТА'ТЬ** II *сов. разг.* — 1. очып чыгу, очып әйләнеп чыгу; *он излетал на самолёте всю Европу* — ул самолётта бөтен Европаны очып әйләнеп чыкты; 2. очып бетерү, очып тутыру; *мотор самолёта уже излетал свой срок* — самолёт моторы үз срогын очып тутырды (бетерде) инде.

**ИЗЛЕТЕ'ТЬ** *сов. книж. устар. поэт.* — очып чыгу.

**ИЗЛЕЧЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — 1. *офиц.* дәвалану; *отправить в госпиталь на излечение* — госпитальгә дәвалануга җибәрү; 2. терелү, терелеп житү.

**ИЗЛЕ'ЧИВАТЬ** *несов. книж.* — к. излечить.

**ИЗЛЕ'ЧИВАТЬСЯ** *несов. книж.* — 1. к. излечиться; 2. *страд.* дәвалап терелтелү, дәвалап савыктырылу.

**ИЗЛЕЧИ'МЫЙ** *книж.* — дәвалап төзәтерлек, төзәлерлек.

**ИЗЛЕЧИ'ТЬ** *сов. книж.* — дәвалап терелтү, дәвалап төзәтү, савыктыру.

**ИЗЛЕЧИ'ТЬСЯ** *сов. книж.* — 1. (*совсем вылечиться*) терелү, терелеп житү, савыгу, төзәлү, сәламәтләнеп житү; 2. *перен.* (*избавиться от чего-н. дурного*) котылу, арыну.

**ИЗЛИВА'ТЬ** *несов. книж.* — к. излить.

**ИЗЛИВА'ТЬСЯ** *несов. книж.* — 1. к. излиться; 2. *устар.* агып чыгу; *из скалы изливался источник* — кыядан чишмә агып чыга иде; 3. *устар.* кою, кушылу; *река изливалась в море* — елга диңгезгә коя иде.

**ИЗЛИЗА'ТЬ** *сов. разг.* — ялап бетерү; *собака излизала мне руки* — эт кулларымны ялап бетерде.

**ИЗЛИ'ЗЫВАТЬ** *несов. разг.* — к. излизать.

**ИЗЛИ'ТЬ** *сов. книж.* — 1. *устар. поэт.* кою, түгү; *излить потоки слёз* — күп яшь түгү; 2. *перен. устар. поэт.* чәчү, сибү; *луна вышла из-за туч и излила мягкий свет* — ай болытлар арасыннан чыкты һәм йомшак нурын чәчте; 3. белдерү, яудыру; *излить свою благодарность* — үзеннең рәхмәтләренне белдерү; 4. бушату; *излить свой гнев* — үзеннең ачуыңны бушату.

**ИЗЛИ'ТЬСЯ** *сов. книж.* — 1. *устар. поэт.* коелу, түгелү; *излились потоки слёз* — күп яшь түгелде; 2. *перен. устар. поэт.* чәчелү, сибелү, балку; *излился мягкий свет луны* — айның йомшак нуры балкыды; 3. *устар.* белдерелү; *благодарность излилась в прочувственных словах* — рәхмәт йөрәктән чыккан сүзләр белән белдерелде; 4. *устар.* юнәлдерелү; *его гнев излился на всех* — аның ачуы барлык кешеләргә юнәлдерелде; 5. яудыру, белдерү; *он излился в выражениях благодарности* — ул рәхмәт сүзләре яудырды.

**ИЗЛИ'ШЕК** *м.* — 1. калдык; *сдача излишков* — калдыкны кайтарып бирү (тапшыру); 2. кирәгеннән артык; *излишек темперамента* — кирәгеннән артык темпераментлы булу. ◇ С излишком — артыгы белән; *нам этого хватит с излишком* — безгә бу артыгы белән житәр.

**ИЗЛИ'ШЕСТВО** *ср. книж.* — нормадан артыклык, кирәгеннән артыклык, кирәгеннән артык куллану.

**ИЗЛИ'ШЕСТВОВАТЬ** *несов. книж. устар.* — кирәгеннән артык куллану; *излишествовать в пище* — азыкны кирәгеннән артык куллану.

**ИЗЛИ'ШНИЙ** *книж.* — артык, кирәгеннән артык.

**ИЗЛИЯ'НИЕ** *ср. книж.* — 1. *спец. книж. устар.* (*о жидкости*) агып чыгу; 2. *чаще мн. перен.* күңел бушату, кичерешләрне сөйләп бирү; *дружеские излияния* — кичерешләрне дусларча сөйләп бирү.

**ИЗЛОВИ'ТЬ** *сов. простореч.* — тоту, тотып алу, эләктереп алу; *изловить вора* — каракны тотып алу, каракны тоту.

**ИЗЛОВЧА'ТЬСЯ** *несов. разг.* — к. изловчиться.

**ИЗЛОВЧИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — ипләшү, җайлашу; рәтен табу, җаен табу, җаен туры китерү; *изловчился и ударил его в грудь* — җаен туры китереп аның күкрәгенә сукты.

**ИЗЛОЖЕ'НИЕ** *ср. книж.* — 1. (*действие*) к. изложить; 2. (*стиль и построение рассказа, повествования*) язылыш, язу стиле, сөйләнеш, хикәяләү стиле; 3. (*письменный пересказ*) изложение, иншa.

**ИЗЛОЖИ'ТЬ** *сов. книж.* — язып бирү; сөйләп бирү, сөйләп аңлату.

**ИЗЛО'ЖНИЦА** *ж.*, **ИЗЛО'ЖНЯ** *ж. тех.* — калып (корыч һ. б. металларны эретеп кою эшендә).

**ИЗЛО'М** *м. книж.* — 1. (*действие*) к. изломить, изломиться; 2. сынган урын, ватылган урын; *на самом изломе столб оказался гнилым* — нәкъ сынган урында багана черегән булып чыкты; 3. *перен.* текә борылыш; *изломы реки* — елганың текә борылышлары.

**ИЗЛОМА'ТЬ** *сов.* — 1. (*сломать целиком*) ватып бетерү, сындырып бетерү; 2. *простореч.* хәлдән тайдыру; *лихорадка изломала его* — бизгәк аны хәлдән тайдырды; 3. *перен. разг.* бозып бетерү; *изломать характер* — характерын бозып бетерү.

**ИЗЛОМА'ТЬСЯ** *сов.* — 1. (*сломаться совсем*) ватылып бетү, сынып бетү; 2. *перен. разг. фам.* (*стать несносным ломакой*) кыланчыкка әйләнеп бетү.

**ИЗЛОМИ'ТЬ** *сов. простореч.* — сындыру.

**ИЗЛОХМА'ТИТЬ** *сов. простореч.* — тузгытып бетерү, сәләмәләндереп бетерү; *излохматить голову* — чәчне тузгытып бетерү.

**ИЗЛОХМА'ТИТЬСЯ** *сов. простореч.* — сәләмәләнеп бетү, тузып бетү.

**ИЗЛУПИ'ТЬ** *сов. простореч. вульг.* — кыйнап ташлау, тукмап ташлау.

**ИЗЛУЧА'ТЬ** *несов. книж.* — 1. чәчү, сибү, тарату; *солнце излучает тепло* — кояш җылылык тарата; 2. *перен. поэт.* (*о глазах*) балку, сибү, чәчү; *её глаза излучали тихую радость* — аның күзләрендә тыныч шатлык балкый иде.

**ИЗЛУЧА'ТЬСЯ** *несов. книж.* — 1. (*о лучистой энергии*) таралу, чәчелү, сибелү; 2. *перен. поэт.* аңкып тору; балкып тору; *из его глаз излучалась доброта* — аның күзләрендә яхшылык балкып тора иде.

**ИЗЛУ'ЧИНА** *ж. обл. книж.* — текә борылыш, текә борылма; *река делает несколько излучин* — елга берничә текә борылыш ясый.

**ИЗЛУЧИ'ТЬ** *сов. книж.* — к. излучать.

**ИЗЛУЧИ'ТЬСЯ** *сов. книж.* — к. излучаться I.

**ИЗЛЮБИ'ТЬ** *сов. книж. устар.* — бик нык ярату.

**ИЗЛЮ'БЛЕННЫЙ** — яраткан, иң яраткан; *излюбленное занятие* — иң яраткан эш.

**ИЗМА'ЗАТЬ** *сов. разг.* — 1. пычратып бетерү, буяп бетерү; *измазать стол чернилами* — өстәлне кара белән пычратып бетерү; 2. тотып бетерү (сөртергә, буярга, майларга тотыла торган әйберләр турында); *измазал весь дёготь* — бөтен дегетне тотып бетердем.

**ИЗМА'ЗАТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. пычранып бетү, буялып бетү; *измазаться в краске* — буяуга пычранып бетү; 2. тотылып бетү (сөртергә, буярга, майларга кулланыла торган әйберләр турында).

**ИЗМА'ЗЫВАТЬ** *несов. разг.* — к. измазать.

**ИЗМА'ЗЫВАТЬСЯ** *несов. разг.* — к. измазаться.

**ИЗМАЛЕВА'ТЬ** *сов. разг. фам.* — 1. *неодобр.* буяп пычратып бетерү; *измалевал всю стену карандашом* — бөтен стенаны карандаш белән буяп пычратып бетергән; 2. *редко* тотып бетерү (буяуны).

**ИЗМАЛЁВЫВАТЬ** *несов. разг. фам.* — к. измалевать.

**ИЗМАЛЁВЫВАТЬСЯ** *несов. страд., разг. фам.* — буяп пычратып бетерелү.

**ИЗМА'ЛЫВАТЬ** *несов.* — к. измолоть.

**ИЗМА'ЛЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. измолоться; 2. *страд.* тартып бетерелү (ашлык).

**ИЗМАНЕ'РНИЧАТЬСЯ** *сов. разг. фам.* — кыланчыкка әйләнеп бетү.

**ИЗМАРА'ТЬ** *сов. разг.* — пычратып бетерү, буяп бетерү, тапландырып бетерү.

**ИЗМАРА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — пычранып бетү, буялып бетү.

**ИЗМА'РЫВАТЬ** *несов. разг.* — к. измарать.

**ИЗМА'РЫВАТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. к. измараться; 2. *страд.* пычратып бетерелү, буяп бетерелү, таплантырып бетерелү.

**ИЗМА'СЛИВАТЬ** *несов. разг.* — к. измаслить.

**ИЗМА'СЛИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. к. измаслиться; 2. *страд.* майга пычратып бетерелү.

**ИЗМА'СЛИТЬ** *сов. разг.* — майга пычратып бетерү.

**ИЗМА'СЛИТЬСЯ** *сов. разг.* — майга пычранып бетү.

**ИЗМА'ТЫВАТЬ** *несов. разг.* — к. измотать.

**ИЗМА'ТЫВАТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. к. измотаться; 2. *страд.* хәлдән тайдырылу.

**ИЗМА'ЧИВАТЬ** *несов. разг.* — к. измочить.

**ИЗМА'ЧИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. к. измочиться; 2. *страд.* юешләп бетерелү, чылатып бетерелү.

**ИЗМА'ЯТЬ** *сов. просторечь.* — хәлдән тайдыру, әлсерәтеп бетерү, ардырып бетерү; *дорога измаяла его* — юл аны ардырып бетергән.

**ИЗМА'ЯТЬСЯ** *сов. просторечь.* — хәлдән таю, азапланып бетү, арып бетү; *измаяться в дороге* — юлда азапланып бетү, юлда арып бетү.

**ИЗМЕЛИ'ТЬ** *сов. разг.* — 1. акбурга пычрату; *измелить руки* — кулларны акбурга пычрату; 2. тотып бетерү (акбурны).

**ИЗМЕЛИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. *просторечь.* акбурга пычрану; 2. тотылып бетү (акбур).

**ИЗМЕЛЬЧА'ТЬ** I *сов.* — 1. саегу; *озеро измельчало* — күл саеккан; 2. *перен.* вагаю, түбәнәю; *интересы измельчали* — интереслар түбәнәйделәр.

**ИЗМЕЛЬЧА'ТЬ** II *несов. спец.* — к. измельчить.

**ИЗМЕЛЬЧА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. *спец.* к. измельчиться; 2. *страд.* ваклап бетерелү.

**ИЗМЕЛЬЧИ'ТЬ** *сов.* — ваклап бетерү.

**ИЗМЕЛЬЧИ'ТЬСЯ** *сов. спец.* — ваклanып бетү.

**ИЗМЕ'НА** *ж.* — хыянәт, хыянәт итү; сату, сатылу.

**ИЗМЕНЕ'НИЕ** *ср.* — 1. үзгәрү; үзгәртү; *изменение голоса* — тавышның үзгәрүе, тавышны үзгәртү; 2. *грам.* төрләнү; төрләндерү; *изменение слова по падежам* — сүзнең килешләр белән төрләнүе, сүзне килешләр белән төрләндерү; 3. үзгәреш; *внести изменения в статью* — мәкаләгә үзгәрешләр кертү.

**ИЗМЕНИ'ТЬ** *сов.* — 1. үзгәртү; *изменить свою жизнь* — үз тормышыңны үзгәртү; 2. хыянәт итү, сатылу, сату; *изменить родине* — ватанга хыянәт итү; 3. кире кайту, читкә кагу; *изменить решению* — карардан кире кайту; 4. *перен.* алдау, ярдәм итмәү; *на этот раз память изменила ему* — бу юлы хәтере аны алдады (ярдәм итмәде); 5. *грам.* төрләндерү; *изменить слово по падежам* — сүзне килешләр белән төрләндерү.

**ИЗМЕНИ'ТЬСЯ** *сов.* — үзгәрү; *настроение его изменилось* — аның кәефе үзгәрде.

**ИЗМЕ'ННИК** *м.*, **ИЗМЕ'ННИЦА** *ж.* — 1. (*предатель*) хыянәтче, сатлык җан; 2. *разг.* (*нарушитель верности в любви*) хыянәтче, алдакчы.

**ИЗМЕ'ННИЧЕСКИ** *нареч.* — хыянәтчеләрчә.

**ИЗМЕ'ННИЧЕСКИЙ** *книж.* — хыянәтчеләр...-ы; хыянәтчегә хас, сатлык җанга хас; хыянәтчел; *изменнические действия* — хыянәтчел эшләр.

**ИЗМЕ'ННИЧЕСТВО** *ср. книж. устар.* — хыянәт, хыянәтчелек.

**ИЗМЕ'НЧИВОСТЬ** *ж. мн.* нет — үзгәрүчәнлек, алмашынып торучанлык; *изменчивость погоды* — һаваның үзгәрүчәнлеге.

**ИЗМЕ'НЧИВЫЙ** — үзгәрүчән, алмашынып торучан.

**ИЗМЕ'НЩИК** *м.*, **ИЗМЕ'НЩИЦА** *ж.* — к. изменник 2.

**ИЗМЕНЯ'ЕМОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — үзгәрүчәнлек; төрләнүчәнлек, төрләнү; *изменяемость слова по падежам* — сүзнең килешләр белән төрләнүчәнлеге.

**ИЗМЕНЯ'ТЬ** *несов.* — к. изменить.

**ИЗМЕНЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. измениться; 2. *страд.* үзгәртелү; 3. *грам.* төрләнү; *существительные изменяются по падежам*

*и числам* — исемнәр килешләр һәм сан белән төрләнәләр.

**ИЗМЕРЕ'НИЕ** *ср.* — үлчәү; *измерение роста* — буйны үлчәү; *куб имеет три измерения: длину, высоту и ширину* — кубның өч үлчәве бар: озынлык, биеклек һәм киңлек.

**ИЗМЁРЗНУТЬ** *сов. просторечь.* — бик нык туңу, туңып бетү, өшеп бетү.

**ИЗМЕРИ'ТЕЛЬ** *м. спец.* — 1. *тех.* (*прибор*) үлчәү, үлчәгеч; 2. (*показатель*) күрсәткеч.

**ИЗМЕРИ'ТЕЛЬНЫЙ** *спец.* — үлчәү...-ы; *измерительный прибор* — үлчәү приборы.

**ИЗМЕ'РИТЬ** *сов.* — 1. үлчәү, үлчәп чыгу; *измерить температуру* — температураны үлчәү; *измерить длину здания* — бинаның озынлыгын үлчәп чыгу; 2. *перен. книж.* белү; *измерить глубину чувства* — хисснең тирәнлеген белү.

**ИЗМЕРЯ'ТЬ** *несов.* — к. измерить.

**ИЗМЕРЯ'ТЬСЯ** *несов.* — үлчәнү.

**ИЗМЕЩА'НИТЬСЯ** *сов. разг. неодобр.* — мещанлашу, мещанлашып бетү.

**ИЗМИНА'ТЬ** *несов. редко* — к. измять.

**ИЗМИНА'ТЬСЯ** *несов. редко* — 1. к. измяться; 2. *страд.* таушалдырып бетерелү, изрәтеп бетерелү.

**ИЗМОКА'ТЬ** *несов. разг.* — к. измокнуть.

**ИЗМО'КНУТЬ** *сов. разг.* — чылану, чыланып бетү, юешләнеп бетү, манма су булу.

**ИЗМОЛА'ЧИВАТЬ** *несов. с.-х.* — к. измолотить.

**ИЗМОЛА'ЧИВАТЬСЯ** *несов. с.-х.* — к. измолотиться.

**ИЗМОЛО'Т** *м. с.-х.* — төшем, чыгыш (сугылган ашлыкның микъдары).

**ИЗМОЛОТИ'ТЬ** *сов. с.-х.* — сугып бетерү (ашлыкны).

**ИЗМОЛОТИ'ТЬСЯ** *сов. с.-х.* — сугылып бетү.

**ИЗМОЛО'ТЬ** *сов. с.-х.* — тарттырып бетерү (ашлыкны).

**ИЗМОЛО'ТЬСЯ** *сов.* 1. *с.-х.* тартылып бетү (ашлык); 2. *просторечь. пренебр.* лыгырдап теңкәгә тию, лыгырдый-лыгырдый тәмен китерү.

**ИЗМО'Р** *м. мн.* нет, *устар.*: взять измором — 1. ачлыктан интектереп алу; *взять осаждённый город измором* — камалган шәһәрне (халкын) ачлыктан интектереп алу; 2. *разг. перен.* үзәгенә үтеп алу; теңкәсенә тиеп алу; *хоть измором, а возьму с него долг* — үзәгенә үтеп булса да, аласымны мин аннан алырмын.

**ИЗМОРИ'ТЬ** *сов. просторечь.* — алҗытып бетерү, йөдәтеп бетерү, интектереп бетерү, арытып бетерү, хәлдән тайдыру.

**ИЗМОРИ'ТЬСЯ** *сов. просторечь.* — бик нык ару, алҗып бетү, хәлдән таю.

**ИЗМОРО'ЗИТЬ** *сов. просторечь.* — өшетеп бетерү, туңдырып бетерү.

**И'ЗМОРОЗЬ** *ж. мн.* нет, *обл.* — к. иней.

**И'ЗМОРОСЬ** *ж. мн.* нет — пыскак яңгыр, бик вак яңгыр.

**ИЗМОРЩИ'НИТЬ** *сов. разг. редко* — җыерчыклап бетерү, җыерчыкландырып бетерү.

**ИЗМОРЩИ'НИТЬСЯ** *сов. разг. редко* — җыерчыкланып бетү.

**ИЗМОТА'ТЬ** *сов. разг.* — арытып бетерү, хәлдән тайдырып бетерү, әлсерәтеп бетерү.

**ИЗМОТА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — хәлдән таю, арып бетү, бик нык ару, әлсерәү, әлсерәп бетү.

**ИЗМОЧА'ЛИВАТЬ** *несов. разг.* — к. измочалить.

**ИЗМОЧА'ЛИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. к. измочалиться; 2. *страд.* сусәртеп бетерелү, мунчалаландырып бетерелү.

**ИЗМОЧА'ЛИТЬ** *сов. разг.* — 1. сусәртеп бетерү, мунчалаландырып бетерү; 2. *перен. просторечь.* җәфалап бетерү, интектереп бетерү, газаплап бетерү.

**ИЗМОЧА'ЛИТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. сусәреп бетү, тетелеп бетү, мунчалаланып бетү; 2. *просторечь.* арып бетү, йөдәп бетү, газапланып бетү, хәлдән таю, эштән чыгу.

**ИЗМОЧИ'ТЬ** *сов. разг.* — юешләп бетерү, чылатып бетерү.

**ИЗМОЧИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — юешләнеп бетү, чыланып бетү.

**ИЗМОШЕ'ННИЧАТЬСЯ** *сов. разг.* — хыянәтчегә әйләнү, чеп-чи алдакчыга әйләнү.

**ИЗМУ'СЛИВАТЬ** *несов. просторечь.* — к. измуслить.

**ИЗМУ'СЛИВАТЬСЯ** *несов. просторечь.* — 1. к. измуслиться; 2. *страд.* селәгәйгә пычратып бетерелү, селәгәйгә буяп бетерелү.

**ИЗМУ'СЛИТЬ** *сов. просторечь.* — селәгәйгә буяп бетерү, селәгәйгә пычратып бетерү, селәгәйләндереп бетерү.

**ИЗМУ'СЛИТЬСЯ** *сов. просторечь.* — селәгәйгә буялып бетү, селәгәйгә пычранып бетү.

**ИЗМУСО'ЛИВАТЬ** *несов. просторечь.* — к. измусолить.

**ИЗМУСО'ЛИВАТЬСЯ** *несов. просторечь.* — к. измусолиться.

**ИЗМУСО'ЛИТЬ** *сов. просторечь.* — к. измуслить.

**ИЗМУСО'ЛИТЬСЯ** *сов. просторечь.* — к. измуслиться.

**ИЗМУ'ЧИВАТЬ** *несов. просторечь.* — к. измучить.

**ИЗМУ'ЧИВАТЬСЯ** *несов. просторечь.* — к. измучиться.

**ИЗМУ'ЧИТЬ** *сов.* — җәфалап бетерү, интектереп бетерү, хәлдән тайдыру.

**ИЗМУ'ЧИТЬСЯ** *сов.* — җәфаланып бетү, интегеп бетү, хәлдән таю, йөдәп бетү.

**ИЗМЫВА'ТЕЛЬСКИЙ** *разг. фам.* — к. издевательский.

**ИЗМЫВА'ТЕЛЬСТВО** *ср. разг. фам.* — к. издевательство.

**ИЗМЫВА'ТЬСЯ** *несов. разг. фам.* — к. издеваться.

**ИЗМЫ'ЗГАТЬ** *сов. просторечь.* — бөтенләй пычратып бетерү, бөтенләй буяп бетерү.

**ИЗМЫ'ЗГАТЬСЯ** *сов. просторечь.* — бөтенләй пычранып бетү, шапшакланып бетү, бөтенләй буялып бетү.

**ИЗМЫ'ЗГИВАТЬ** *несов. просторечь.* — к. измызгать.

**ИЗМЫ'ЗГИВАТЬСЯ** *несов. просторечь.* — к. измызгаться.

**ИЗМЫ'ЛИВАТЬ** *несов.* — к. измылить.

**ИЗМЫ'ЛИВАТЬСЯ** *несов.* — к. измылиться.

**ИЗМЫ'ЛИТЬ** *сов.* — тотып бетерү (сабынны).

**ИЗМЫ'ЛИТЬСЯ** *сов. разг.* — тотылып бетү (сабын).

**ИЗМЫ'СЛИТЬ** *сов. книж. редко* — к. измышлять.

**ИЗМЫТА'РИТЬ** *сов. разг. фам.* — интектереп бетерү, газап чиктерү, йөдәтеп бетерү, алҗытып бетерү.

**ИЗМЫТА'РИТЬСЯ** *сов. разг. фам.* — интегеп бетү, газап чигү, йөдәп бетү, алҗып бетү.

**ИЗМЫШЛЕ'НИЕ** *ср. книж.* — 1. к. измышлять; 2. к. выдумка.

**ИЗМЫШЛЯ'ТЬ** *несов. книж.* — 1. *(выдумывать ложное)* — ялган уйлап чыгару, яла уйлап чыгару; 2. *(придумывать, изобретать)* уйлап табу, уйлап чыгару.

**ИЗМЫШЛЯ'ТЬСЯ** *несов. страд. книж.* — 1. яла уйлап чыгарылу, ялган уйлап чыгарылу; 2. уйлап табылу, уйлап чыгарылу.

**ИЗМЯ'КАТЬ** *несов. разг.* — к. измякнуть.

**ИЗМЯ'КНУТЬ** *сов. разг.* — йомшап бетү, йомшарып бетү, изрәп бетү.

**ИЗМЯ'ТЬ** *сов.* — 1. таушалдырып бетерү, бөрештереп бетерү; *измять платье* — күлмәкне таушалдырып бетерү, бөрештереп бетерү; 2. *(давя, размягчить)* изрәтеп бетерү, изеп йомшартып бетерү.

**ИЗМЯ'ТЬСЯ** *сов.* — таушалып бетү, бөрешеп бетү.

**ИЗНА'НКА** *ж.* — 1. *(обратная, внутренняя сторона)* сулъяк, эчке як, тискәре як (тукыманың, киемнең); 2. *перен. разг.* *(подоплёка)* сер, яшерен сәбәп, яшерен як (вакыйгада, күренештә). ◇ **На изнанку** — к. наизнанку.

**ИЗНАСИ'ЛОВАТЬ** *сов. книж.* — 1. көчләү, намусына тию; 2. *(насильно заставить изменить что-н.)* мәҗбүр итү, үзгәрттерү, үзгәртергә мәҗбүр итү.

**ИЗНАЧА'ЛА** *нареч. книж. устар.* — электән үк, күптән үк, баштан ук, элек-электән, борын-борыннан.

**ИЗНА'ШИВАЕМОСТЬ** *ж. мн.* нет, *спец.* — тузучанлык, тузу дәрәҗәсе, искерү дәрәҗәсе.

**ИЗНА'ШИВАТЬ** *несов.* — к. износить.

**ИЗНА'ШИВАТЬСЯ** *несов.* — к. износиться.

**ИЗНЕ'ЖЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. иркәлек, назлылык; иркә үсү; *изнеженность ребёнка была причиной частых простуд* — баланың иркә үсүе бик еш салкын тиюгә сәбәп була иде; 2. *перен.* йомшаклык, җебегәнлек.

**ИЗНЕ'ЖЕННЫЙ** — иркә, назлы; *изнеженный человек* — иркә кеше.

**ИЗНЕ'ЖИВАТЬ** *несов.* — к. изнежить.

**ИЗНЕ'ЖИВАТЬСЯ** *несов.* — к. изнежиться.

**ИЗНЕ'ЖИТЬ** *сов.* — иркәләп бозып бетерү, назлап бозып бетерү, артык рәхәткә өйрәтеп бозып бетерү.

**ИЗНЕ'ЖИТЬСЯ** *сов.* — иркәләүдән бозылу, назлаудан бозылу, артык рәхәткә өйрәнеп бозылу.

**ИЗНЕМОГА'ТЬ** *несов. книж.* — к. изнемочь.

**ИЗНЕМОЖЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — хәлсезлек, арганлык.

**ИЗНЕМО'ЧЬ** *сов. книж.* — хәлсезләнү, хәл бетү, хәлдән таю.

**ИЗНЕ'РВНИЧАТЬСЯ** *сов. разг.* — холыксызланып бетү, борчылып бетү.

**ИЗНИЗА'ТЬ** *сов.* — 1. *разг.* тезүгә тотып бетерү; *изнизать весь жемчуг* — бөтен энҗене тезүгә тотып бетерү; 2. *устар.* тезеп матурлау; *изнизать жемчугом парчу* — парчаны энҗе тезеп матурлау.

**ИЗНИЗА'ТЬСЯ** *сов.* — 1. *разг.* тезүгә тотылып бетү; 2. *устар.* *(стать унизанным)* тезеп матурлану.

**И'ЗНИЗУ** *нареч. простореч.* — түбәннән, астан.

**ИЗНИ'ЗЫВАТЬ** *несов.* — к. изнизать.

**ИЗНИ'ЗЫВАТЬСЯ** *несов.* — к. изнизаться.

**ИЗНИЧТОЖА'ТЬ** *несов. книж. устар. простореч.* — к. изничтожить.

**ИЗНИЧТОЖА'ТЬСЯ** *несов. книж. устар.* — 1. к. изничтожиться; 2. *страд.* юк ителү, юкка чыгарылу, кырып бетерелү, нәселе корытылу.

**ИЗНИЧТО'ЖИТЬ** *сов. книж. устар.* — юк итү, юкка чыгарып бетерү, кырып бетерү, нәселен корыту.

**ИЗНИЧТО'ЖИТЬСЯ** *сов. книж. устар., теперь простореч.* — юкка чыгу, кырылып бетү, нәселе кору.

**ИЗНИЩА'ТЬ** *сов. редко* — хәерчеләнеп бетү, ярлыланып бетү.

**ИЗНОРОВИ'ТЬСЯ** *сов. обл.* — к. изловчиться.

**ИЗНО'С** *м.*: **не знать износу (-а)** — туза белмәү, озакка чыдау; **до износу (-а)** — тузганчы, тузып беткәнче; **нет износу (-а)** — нык, чыдамлы.

**ИЗНОСИ'ТЬ** *сов.* — киеп туздыру, туздырып бетерү.

**ИЗНОСИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. *(прийти в негодность)* тузып бетү; 2. *перен. разг.* *(преждевременно истощить свои силы)* көч бетү, таушалу, вакытыннан элек картаю.

**ИЗНО'ШЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — 1. искергәнлек, таушалганлык, тузганлык; искерү дәрәҗәсе, тузу дәрәҗәсе; 2. *перен. разг.* картайганлык, йончыганлык.

**ИЗНУРЁННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — йончыганлык, ябыкканлык, йөдәгәнлек, талчыкканлык.

**ИЗНУРИ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — йончыткыч булу, йөдәткеч булу, интектергеч булу.

**ИЗНУРИ'ТЕЛЬНЫЙ** — йончыткыч, хәлдән тайдыргыч, чиксез авыр.

**ИЗНУРИ'ТЬ** *сов. книж.* — йончытып бетерү, ябыктырып бетерү, интектереп бетерү, хәлсезләндереп бетерү, арытып бетерү, талчыктырып бетерү.

**ИЗНУРИ'ТЬСЯ** *сов. книж.* — йончып бетү, хәлсезләнеп бетү, арып бетү, талчыгып бетү.

**ИЗНУРЯ'ТЬ** *несов. книж.* — к. изнурить.

**ИЗНУРЯ'ТЬСЯ** *несов. книж.* — 1. к. изнуриться; 2. *страд.* йончытып бетерелү, интектереп бетерелү.

**ИЗНУТРИ'** *нареч.* — 1. эчтән, эчке яктан; *комната заперта изнутри* — бүлмә эчке яктан бикле; 2. эчтән, уртадан, уртасыннан; *бревно прогнило изнутри* — бүрәнә эчтән (уртадан) черегән.

**ИЗНЫВА'ТЬ** *несов.* — к. изныть.

**ИЗНЫРЯ'ТЬ** *сов. разг.* — чумып актарып бетерү, чумып күп урында булу (мәсәлән, елганың, күлнең күп урынында); *изныряли всю реку, а трупа не нашли* — чумып бөтен елганы актарып бетердек, мәетне (батып үлгән кешене) тапмадык.

**ИЗНЫ'ТЬ** *сов.* — 1. интегү, интегеп бетү, йөдәү, йөдәп бетү, җәфалану, җәфаланып бетү; 2. *поэт.* сагынып бетү, сагынып саргаеп бетү, сагынып кибеп бетү.

**ИЗО** *предлог с род. п.* — к. из; *изо дня в день* — көннән-көнгә; көннән-көн, көн саен, һәр көнне; *состояние больного изо дня в день улучшается* — авыруның хәле көннән-көн яхшыра бара; *изо рта* — авыздан.

**ИЗОБА'РА** *ж. геогр.* — изобара (географик картада атмосфера басымы бер үк дәрәҗәдә булган урыннарны тоташтыра торган сызык).

**ИЗОБА'ТЫ** *мн. геогр.* — изобаталар (географик картада су бассейннарының бер үк тирәнлектә булган урыннарын тоташтыра торган сызыклар).

**ИЗОБИ'ДЕТЬ** *сов. разг. обл.* — бик нык кыерсыту, кәефен кыру, бик нык үпкәләтү.

**ИЗОБИ'ЛИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — күплек, муллык, байлык.

**ИЗОБИ'ЛОВАТЬ** *несов. книж.* — бик күп (булу), бай (булу), мул (булу); *озеро изобилует рыбой* — күл балыкка бай.

**ИЗОБИ'ЛЬНЫЙ** — бик күп, бик мул, бай.

**ИЗОБЛИЧА'ТЬ** *несов. книж.* — к. изобличить.

**ИЗОБЛИЧА'ТЬСЯ** *несов. страд. книж.* — фаш ителү, гаебе ачылу, чын йөзе ачылу.

**ИЗОБЛИЧИ'ТЕЛЬ** *м. книж.* — фаш итүче, гаебен ачучы, чын йөзен ачучы.

**ИЗОБЛИЧИ'ТЕЛЬНЫЙ** — фаш итә торган, гаебен ача торган.

**ИЗОБЛИЧИ'ТЬ** *сов. книж.* — фаш итү, гаебен ачу, чын йөзен ачу.

**ИЗОБРАЖА'ТЬ** *несов.* — 1. к. изобразить 1, 2, 3, 4; 2. *книж.* тасвирлау, гәүдәләндерү, сурәтләү; *картина изображает закат солнца* — картина кояш баешын сурәтли.

**ИЗОБРАЖА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. *книж.* к. изобразиться; 2. *страд.* гәүдәләндерелү.

**ИЗОБРАЖЕ'НИЕ** *ср. книж.* — 1. к. изобразить; 2. сурәт, сын, рәсем; *монета с изображением герба* — герб сурәте төшерелгән акча; *на столе стояло каменное изображение* — өстәлдә таш сын тора иде.

**ИЗОБРАЗИ'ТЕЛЬ** *м. книж.* — тасвирлаучы, сурәтләүче, гәүдәләндерүче.

**ИЗОБРАЗИ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — сурәтлелек.

**ИЗОБРАЗИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.* — сурәтләү...-ы; *изобразительный приём* — сурәтләү алымы. ◇ Изобразительное искусство — сынлы сәнгать.

**ИЗОБРАЗИ'ТЬ** *сов.* — 1. тасвирлау, сурәтләү; *художник изобразил море* — художник диңгезне сурәтләгән; *Гоголь в „Мертвых душах" изобразил помещичий быт* — "Үле җаннар"да Гоголь алпавытлар тормышын тасвирлаган; 2. гәүдәләндерү; *артист изобразил Хлестакова ловким плутом* — артист Хлестаковны оста ялганчы итеп гәүдәләндерде; 3. *книж.* күрсәтү, чагылдыру; *лицо его изобразило неподдельную скорбь* — аның йөзе чын кайгыны чагылдырды; 4. *разг.* ... булып кылану, ... итеп күрсәтергә маташу; *он изобразил из себя революционера* — ул үзен революционер итеп күрсәтергә маташты; 5. *простореч. фам.* уйнау, уйнап күрсәтү; уйнап бирү; *изобрази-ка нам на гармони!* — гармоньда уйнап күрсәт әле безгә!

**ИЗОБРАЗИ'ТЬСЯ** *сов.* — гәүдәләнү, сурәтләнү, тасвирлану; күренү, күзгә чагылу; *горе изобразилось на лице девочки* — кызның йөзендә кайгы күренде.

**ИЗОБРЕСТИ'** *сов.* — уйлап чыгару, уйлап табу; *изобрести машину* — машина уйлап чыгару.

**ИЗОБРЕТА'ТЕЛЬ** *м.*, **ИЗОБРЕТА'ТЕЛЬНИЦА** *ж.* — уйлап табучы, уйлап чыгаручы (хатын).

**ИЗОБРЕТА'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — уйлап табучанлык, уйлап табу сәләте.

**ИЗОБРЕТА'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.* — тапкыр, уйлап табучан; уйлап табуга сәләтле; уйлап таба торган; *изобретательный на всякие фокусы* — һәртөрле фокусларга тапкыр кеше, һәртөрле фокуслар уйлап табуга сәләтле кеше.

**ИЗОБРЕТА'ТЕЛЬСКИЙ** *книж.* — уйлап табучылар...-ы; *изобретательское бюро* — уйлап табучылар бюросы.

**ИЗОБРЕТА'ТЕЛЬСТВО** *ср. мн.* нет, *книж.* — уйлап табу, уйлап чыгару, уйлап табуга һәвәслек.

**ИЗОБРЕТА'ТЬ** *несов.* — к. изобрести.

**ИЗОБРЕТА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — уйлап чыгарылу, уйлап табылу.

**ИЗОБРЕТЕ'НИЕ** *ср.* — 1. *только ед.* уйлап табу, уйлап чыгару; *изобретение новой машины* — яңа машина уйлап табу; 2. уйлап табылган әйбер.

**ИЗОВРА'ТЬСЯ** *сов. простореч.* — к. изолгаться.

**ИЗОГИЕ'ТЫ** *мн. геогр.* — изогиеталар (географик картада еллык явым-төшем бертигез булган урыннарны тоташтыра торган сызыклар).

**ИЗОГИ'ПСЫ** *мн. геогр.* — изогипслар (географик картада бертигез биеклектә булган урыннарны тоташтыра торган сызыклар).

**ИЗОГЛО'ССА** *ж. лингв.* — изоглосса (географик картада тел үзенчәлекләре бертөрле булган урыннарны тоташтыра торган сызык).

**ИЗОГНУ'ТЬ** *сов.* — к. изгибать.

**ИЗОГНУ'ТЬСЯ** *сов.* — к. изгибаться.

**ИЗОГО'НЫ** *мн. геогр.* — изогоналар (географик картада җир өстенең магнит

авышлыгы бертөрле булган урыннарын тоташтыра торган сызыклар).

**ИЗОДРА'ТЬ** *сов. простореч.* — ертып бетерү, ерткалап бетерү.

**ИЗОДРА'ТЬСЯ** *сов. простореч.* — ертылып бетү, ерткаланып бетү.

**ИЗОЙТИ'** *сов.* — хәлдән таю, көчсезләнү; *изойти слезами* — елый-елый хәлдән таю; *изойти кровью* — кан агудан көчсезләнү.

**ИЗОЛГА'ТЬСЯ** *сов.* — алдарга гадәтләнү, ялганларга гадәтләнү, ялганчыга әйләнү.

**ИЗОЛИ'НИИ** *мн. геогр.* — изосызыклар (географик картада нинди дә булса зурлыкны, мәсәлән, халык тыгызлыгын, атмосфера басымын, җәй эсселеген белдерүче күрсәткечләре бертөрле булган урыннарны тоташтыра торган сызыклар).

**ИЗОЛИ'РОВАННОСТЬ** *ж. мн.* нет — изоляцияләнгәнлек, читләштерелгәнлек, аерымлык, ялгызлык.

**ИЗОЛИ'РОВАННЫЙ** *книж.* — 1. изоляцияләнгән, аерып алынган; 2. аерым, сирәк очрый торган; *изолированный случай* — аерым (сирәк очрый торган) вакыйга.

**ИЗОЛИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. книж.* — 1. аеру, читләштерү, аерып алу; *изолировать ребёнка от вредных влияний* — баланы зарарлы йогынтылардан читләштерү; 2. *спец.* изоляцияләү, аеру; *изолировать больного* — авыруны изоляцияләү (сәламәт кешеләрдән аеру); 3. *тех.* изоляцияләү; *изолировать электрический провод резиновой оболочкой* — электр үткәргечен резина тышча белән изоляцияләү (электр үткәргечен резина тышча белән чорнау).

**ИЗОЛИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. книж.* — 1. (*отъединиться*) аерылу, читләшү, изоляцияләнү; 2. *страд.* изоляцияләндерелү, читләштерелү.

**ИЗОЛИРО'ВОЧНЫЙ** *тех.* — изоляция...-ы; изоляцияләү...-ы; *изолировочные материалы* — изоляция материаллары, изоляцияләү материаллары.

**ИЗОЛИРО'ВЩИК** *м. спец.* — изолировщик (1. изоляцияләүче; 2. изоляторлар хәзерләүче).

**ИЗОЛЯ'ТОР** *м.* — изолятор (1. электр тогы үткәрми торган әйбер, мәсәлән, каучук, фарфор, пыяла; 2. *тех.* электр үткәргечен беркетә торган пыяла яки фарфор ролик; 3. *мед.* аерым авырулар өчен бүлмә; 4. *офиц.* ябу урыны, төрмә).

**ИЗОЛЯЦИО'ННЫЙ** *книж.* — изоляция...-ы; *изоляционная камера* — изоляция камерасы.

**ИЗОРВА'ТЬ** *сов.* — ертып бетерү, ерткалап бетерү.

**ИЗОРВА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — ертылып бетү, тузып ертылып бетү.

**ИЗОСТЛА'ТЬ** *сов.* — җәеп тутыру, түшәп бетерү; *изостлал комнату коврами* — бүлмәне паласлар җәеп тутырган.

**ИЗОТЕРМИ'ЧЕСКИЙ** — изотермик (1. *физ.* бердәй температуралы, бердәй температурада була торган; *изотермический процесс* — изотермик процесс, бердәй температурада була торган процесс; 2. *спец.* бердәй температураны саклый торган; *изотермический вагон* — изотермик вагон, бер үк температураны саклый торган вагон).

**ИЗОТЕ'РМЫ** *мн.* — изотермалар (1. *геогр.* географик картада билгеле бер вакытта, мәсәлән, июльдә, уртача температуралары бердәй булган урыннарны тоташтыра торган сызыклар; 2. *физ.* температура бер хәлдә булган вакытта нинди дә булса бер җисемнең үзгәрешен диаграммада күрсәткән кәкре сызыклар).

**ИЗОТЕ'РЫ** *мн. геогр.* — изотералар (географик картада җәй көне температуралары бердәй булган урыннарны тоташтыра торган сызыклар).

**ИЗОТКА'ТЬ** *сов.* — 1. тукып бизәү, тукып матурлау; *изоткать золотом материю* — материяне алтын белән тукып бизәү; 2. *обл.* тукуга тотып бетерү; *изоткала 10 кг пряжи* — тукуга 10 *кг* җеп тотып бетердем.

**ИЗОХИМЕ'НА** *ж. геогр.* — изохимена (географик картада кыш көне температуралары бердәй булган урыннарны тоташтыра торган сызык).

**ИЗОХРО'ННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *науч.* — бер үк дәвамлылыкта булу.

**ИЗОХРО'ННЫЙ** *науч.* — бер үк дәвамлылыктагы; *изохронные колебания* — бер үк дәвамлылыктагы тирбәнүләр.

**ИЗОЩРЁННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — сизгерлек, үткенлек, нечкә тойгылылык; камиллек; *изощрённость ума* — акылның камиллеге.

**ИЗОЩРЁННЫЙ** *книж.* — сизгер, камил, үткен; камилләштерелгән, күнеккән.

**ИЗОЩРИ'ТЬ** *сов. книж.* — үстерү, сизгерләндерү, камилләштерү; *изощрить ум* — акылны үстерү.

**ИЗОЩРИ'ТЬСЯ** *сов. книж.* — 1. үткенләнү, остару, шомару, үсү, камилләшү; *мысль этого учёного изощрилась в философских спорах* — бу галимнең фикере философик бәхәсләрдә шомарган; 2. барысыннан да уздыру; *изощриться в придумывании нелепостей* — ахмаклыклар уйлап чыгаруда барысыннан да уздыру.

**ИЗОЩРЯ'ТЬ** *несов. книж.* — к. изощрить.

**ИЗОЩРЯ'ТЬСЯ** *несов. книж.* — к. изощриться.

**ИЗ-ПО'Д** *предлог* — 1. астыннан; *вылез из-под стола* — өстәл астыннан килеп чыкты; 2. ...-дан бушаган; *кадка из-под мёда* — балдан бушаган кисмәк, бал кисмәге. ◇ **Из-под палки** *разг.* — ирексездән, теләмичә; *работать из-под палки* — теләмичә эшләү. **Из-под носу** *разг.* — күз алдында; *из-под носу украли* — күз алдында урлаганнар.

**ИЗРАЗВРА'ТНИЧАТЬСЯ** *сов. разг.* — бозык кешегә әйләнү, бозыклыкның чигенә җитү.

**ИЗРАЗЕ'Ц** *м.* — чынаяк кирпеч, кафель.

**ИЗРАЗЦО'ВЫЙ** — чынаяк кирпечтән са-

лынган, чынаяк кирпеч җәелгән; *изразцовая печь* — чынаяк кирпечтән салынган мич; *изразцовый пол* — чынаяк кирпеч җәелгән идән.

**ИЗРА'НИТЬ** *сов.* — яралап бетерү, җәрәхәтләп бетерү.

**ИЗРАСХО'ДОВАТЬ** *сов.* — тотып бетерү.

**ИЗРАСХО'ДОВАТЬСЯ** *сов.* — тотылып бетү.

**И'ЗРЕДКА** *нареч.* — сирәк кенә, ара-тирә, сирәк-мирәк, әллә нигә бер, анда бер-монда бер, анда-санда.

**ИЗРЕЖЁННЫЙ** *спец.* — сирәк, сирәк тишелгән, тишелеше сирәк булган; *борьба с изрежённой всхожестью картофеля* — бәрәңгенең сирәк тишелүенә каршы көрәш.

**ИЗРЕ'ЗАТЬ** *сов.* — 1. турап бетерү, тураклап бетерү; телгәләп бетерү; *изрезать материю* — материяне турап бетерү; 2. кискәләп тотып бетерү; *изрезать весь картон на коробки* — барлык катыргыны тартмалар ясауга тотып бетерү; 3. *разг.* кискәләп бозып яки яралап бетерү; *изрезать стол ножом* — өстәлне пычак белән кискәләп бозып бетерү; *изрезать руку* — кулны кискәләп яралап бетерү; 4. *книж.* ергалап бетерү; *бухты изрезали низкий берег* — түбән ярны бухталар ергалап бетергән.

**ИЗРЕЗА'ТЬ** *несов.* *простореч.* — к. изрéзать.

**ИЗРЕ'ЗАТЬСЯ** *сов.* *разг.* — кисеп яраланып бетү.

**ИЗРЕЗА'ТЬСЯ** *несов.* *простореч.* — к. изрéзаться.

**ИЗРЕ'ЗЫВАТЬ** *несов.* — к. изрéзать.

**ИЗРЕ'ЗЫВАТЬСЯ** *несов.* — к. изрéзаться.

**ИЗРЕКА'ТЬ** *несов.* — к. изречь.

**ИЗРЕЧЕ'НИЕ** *ср.* — хикмәтле сүз; *изречения великих людей* — бөек кешеләрнең хикмәтле сүзләре.

**ИЗРЕ'ЧЬ** *сов.* *устар.* — сөйләп бирү, әйтеп бирү; *изречь истину* — хакыйкатьне әйтеп бирү.

**ИЗРЕШЕ'ТИ'ТЬ** *сов.* *разг.* — тишкәләп бетерү, челтәрләп бетерү, иләкләндереп бетерү; *его изрешетили пулями* — аны пулялар белән тишкәләп бетергәннәр.

**ИЗРЕШЕ'ТИ'ТЬСЯ** *сов.* *разг.* — тишкәләнеп бетү, челтәрләнеп бетү.

**ИЗРЕШЕ'ЧИВАТЬ** *несов.* *разг.* — к. изрешетить.

**ИЗРЕШЕ'ЧИВАТЬСЯ** *несов.* *разг.* — 1. к. изрешетиться; 2. *страд.* тишкәләп бетерелү, челтәрләп бетерелү.

**ИЗРИ'НУТЬ** *сов.* *книж.* *устар.* — куып чыгару, чыгарып ташлау.

**ИЗРИСОВА'ТЬ** *сов.* — 1. рәсем белән тутыру, рәсем ясап тутыру; *изрисовать бумагу* — кәгазьне рәсем белән (рәсем ясап) тутыру; 2. *разг.* рәсем ясауга тотып бетерү; *изрисовать карандаш* — карандашны рәсем ясауга тотып бетерү.

**ИЗРИСОВА'ТЬСЯ** *сов.* *разг.* — рәсем ясауга тотылып бетү (карандаш турында).

**ИЗРИСО'ВЫВАТЬ** *несов.* — к. изрисовать.

**ИЗРИСО'ВЫВАТЬСЯ** *несов.* — к. изрисоваться.

**ИЗРУБА'ТЬ** *несов.* — к. изрубить.

**ИЗРУБА'ТЬСЯ** *несов.* *страд.* — кискәләнеп бетү, туралып бетү.

**ИЗРУБИ'ТЬ** *сов.* — 1. кискәләп бетерү, турап бетерү; *изрубить доску* — тактаны турап бетерү; 2. *книж.* (*рубя, уничтожить*) кырып бетерү, үтереп бетерү.

**ИЗРУГА'ТЬ** *сов.* *простореч.* — бик нык сүгеп ташлау, бик нык тиргәп ташлау, эт итеп сүгеп ташлау.

**ИЗРЫВА'ТЬ** I *несов.* — к. изорвать.

**ИЗРЫВА'ТЬ** II *несов.* — к. изрыть.

**ИЗРЫВА'ТЬСЯ** I *несов.* — к. изорваться.

**ИЗРЫВА'ТЬСЯ** II *несов.* — казылып бетү, казылып бозылып бетү.

**ИЗРЫГА'ТЬ** *несов.* *книж.* *устар.* — 1. (*извергать изо рта*) косу, косып чыгару; 2. *перен.* (*выбрасывать из себя*) атып чыгару, ургылдыру; *пушки изрыгали дым и пламя* — пушкалар төтен һәм ялкын ургылдыра иде (пушкалардан төтен һәм ялкын ургыла иде); 3. *перен.* әйтү, яудыру (начар сүзләр); *изрыгать ругательства* — әшәке сүзләр яудыру.

**ИЗРЫГНУ'ТЬ** *сов.* *книж.* *устар.* — к. изрыгать.

**ИЗРЫ'СКАТЬ** *сов.* *разг.* — (күп җирләрне) әйләнеп чыгу; *изрыскал весь свет* — бөтен дөньяны әйләнеп чыктым.

**ИЗРЫ'ТЬ** *сов.* — 1. казып бетерү, чокып бетерү, чокырлап бетерү; *снаряды изрыли поле* — снарядлар кырны чокырлап бетергәннәр; 2. *перен.* *простореч.* актарып бетерү; *изрыл весь сундук и ничего не нашёл* — бөтен сандыкны актарып бетердем, бернәрсә дә тапмадым.

**ИЗРЯ'ДНО** *нареч.* — шактый күп.

**ИЗРЯ'ДНЫЙ** — 1. *устар.* яхшы, бик яхшы, менә дигән; *пальто изрядное* — бик яхшы (менә дигән) пальто; 2. *разг.* *фам.* шактый мул, шактый күп, ярыйсы гына, җитәрлек, байтак күп; *я получил изрядную сумму денег* — шактый күп акча алдым. ◇ **Изрядный дурак** — юләрнең юләре. **Изрядный пьяница** — күп эчә торган кеше, исерек баш.

**ИЗУБРА'ТЬ** *сов.* *обл.* — бизәү, матурлау.

**ИЗУВЕ'Р** *м.*, **ИЗУВЕ'РКА** *ж.* *книж.* — явыз, кансыз, үтә шәфкатьсез, усал фанатик (кеше).

**ИЗУВЕ'РСКИЙ** *книж.* — явызларча...; *изуверское отношение* — явызларча мөгамәлә.

**ИЗУВЕ'РСТВО** *ср.* *книж.* — 1. *только ед.* дини фанатиклык; кансызлык; шәфкатьсезлек; 2. шәфкатьсез мөгамәлә; явызларча кыланыш.

**ИЗУВЕ'РСТВОВАТЬ** *несов.* *книж.* — явызларча мөгамәлә итү, явызларча кылану.

**ИЗУВЕ'ЧИВАТЬ** *несов.* — к. изувечить.

**ИЗУВЕ'ЧИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. изувечиться; 2. *страд.* имгәтеп бетерелү, гариплəп бетерелү.

**ИЗУВЕ'ЧИТЬ** *сов.* — имгәтү, имгәтеп бетерү, гарипләндереп бетерү.

**ИЗУВЕ'ЧИТЬСЯ** *сов.* *разг.* — имгәнү, имгәнеп бетү, гарипләнеп бетү.

**ИЗУКРА'СИТЬ** *сов.* — 1. *книж. устар.* бизәү, бизәп матурлау, зиннәтләү; *изукрасить комнату цветами* — бүлмәне чәчәкләр белән бизәү; 2. *разг. ирон.* буяп пычратып бетерү.
**ИЗУКРА'СИТЬСЯ** *сов.* — 1. *книж. устар.* бизәнү; 2. *разг. ирон.* буялып бозылып бетү; буялып пычранып бетү.
**ИЗУКРА'ШИВАТЬ** *несов.* — к. изукрасить.
**ИЗУКРА'ШИВАТЬСЯ** *несов.* — к. изукраситься.
**ИЗУМИ'ТЕЛЬНО** *нареч.* — к. изумительный.
**ИЗУМИ'ТЕЛЬНЫЙ** — искиткеч, таңга калырлык, сокланырлык, шаккатарлык, гаҗәп.
**ИЗУМИ'ТЬ** *сов. книж.* — таңга калдыру, шаккатыру, гаҗәпкә калдыру.
**ИЗУМИ'ТЬСЯ** *сов. книж.* — таңга калу, гаҗәпкә калу, шаккату.
**ИЗУМЛЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — гаҗәпкә калу, шаккату.
**ИЗУМЛЯ'ТЬ** *несов. книж.* — к. изумить.
**ИЗУМЛЯ'ТЬСЯ** *несов. книж.* — к. изумиться.
**ИЗУМРУ'Д** *м.* — зөбәрҗәт (үтә күренмәле, яшел төстәге асылташ).
**ИЗУМРУ'ДНЫЙ** и **ИЗУМРУ'ДОВЫЙ** — 1. зөбәрҗәт чыгару...-ы; *изумрудные копи* — зөбәрҗәт чыгару урыны; 2. зөбәрҗәт кашлы; *изумрудное кольцо* — зөбәрҗәт кашлы йөзек; 3. *поэт.* зөбәрҗәт төсле, яшькелт; *изумрудная вода* — зөбәрҗәт төсле су.
**ИЗУРО'ДОВАТЬ** *сов.* — бозып бетерү, ямьсезләп бетерү, гарипләндереп бетерү, имгәтеп бетерү, гарипләтү, имгәтү.
**ИЗУРО'ДОВАТЬСЯ** *сов.* — бозылып бетү, ямьсезләнеп бетү, гарипләнеп бетү, имгәнеп бетү, гарипләнү, имгәнү.
**ИЗУ'СТНО** *нареч. книж. устар.* — телдән; *условия будут объявлены изустно* — шартлар телдән белдереләчәк.
**ИЗУ'СТНЫЙ** *книж. устар.* — телдән телгә күчә торган, телдән сөйләнә торган; *изустный рассказ* — телдән сөйләнә торган хикәя.
**ИЗУЧА'ТЬ** *несов. книж.* — к. изучить.
**ИЗУЧА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — өйрәнелү.
**ИЗУЧИ'ТЬ** *сов. книж.* — 1. өйрәнү, өйрәнеп житү; *изучить столярное ремесло* — столярлык һөнәрен өйрәнү; 2. өйрәнү, тикшерү; *изучить причины экономического кризиса* — экономик кризисның сәбәпләрен өйрәнү; 3. аңлау, өйрәнеп житү; *я хорошо изучил этого человека* — мин бу кешене бик яхшы аңладым.
**ИЗЪЕДА'ТЬ** *несов.* — к. изъесть.
**ИЗЪЕ'ЗДИТЬ** *сов.* — 1. (автомашинада, поездда һ. б.) йөреп чыгу, гизеп чыгу; *изъездить всю область* — бөтен өлкәне йөреп чыгу; 2. *простореч.* йөреп бозып бетерү, йөреп ватып бетерү; *изъездить дорогу* — юлны йөреп бозып бетерү.
**ИЗЪЕ'ЗДИТЬСЯ** *сов. простореч.* — күп йөрүдән бозылып бетү, күп йөрүдән ватылып бетү; *дорога изъездилась* — юл күп йөрүдән бозылып беткән.
**ИЗЪЕ'ЗЖИВАТЬ** *несов. разг.* — к. изъездить.
**ИЗЪЕ'ЗЖИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — к. изъездиться.
**ИЗЪЕЛО'ЗИТЬ** *сов. разг. фам.* — 1. үрмәләп йөреп чыгу, шуышып йөреп чыгу; *ребёнок изъелозил всю комнату* — бала үрмәләп бөтен бүлмәне йөреп чыкты; 2. *простореч.* шуышып йөреп бозып бетерү (киемне).
**ИЗЪЁРЗАТЬ** *сов. простореч.* — ышкынып тишеп бетерү; *изъёрзать платье* — күлмәкне ышкынып тишеп бетерү.
**ИЗЪЁРЗЫВАТЬ** *несов. простореч.* — к. изъёрзать.
**ИЗЪЕ'СТЬ** *сов.* — 1. ашап бетерү, кимереп бетерү, кисеп бетерү; *моль изъела мех* — мехны көя кисеп бетергән; 2. яндыру, яндырып бетерү; *кислота изъела ткань* — кислота тукыманы яндырып бетергән.
**ИЗЪЯ'БЕДНИЧАТЬСЯ** *сов. простореч.* — гайбәтчегә әверелү, әләкчегә әверелү.
**ИЗЪЯВИ'ТЕЛЬНЫЙ**: изъявительное наклонение *грам.* — хикәя фигыль.
**ИЗЪЯВИ'ТЬ** *сов. книж.* — белдерү, әйтү; *изъявить желание* — теләк белдерү.
**ИЗЪЯВЛЯ'ТЬ** *несов. книж.* — к. изъявить.
**ИЗЪЯВЛЯ'ТЬСЯ** *несов. страд. книж.* — белдерелү.
**ИЗЪЯЗВИ'ТЬ** *сов. книж. устар.* — кутырландырып бетерү.
**ИЗЪЯЗВЛЯ'ТЬ** *несов. книж. устар.* — к. изъязвить.
**ИЗЪЯЗВЛЯ'ТЬСЯ** *несов. страд. книж. устар.* — кутырландырып бетерелү.
**ИЗЪЯ'Н** *м.* — 1. кимчелек, житешсезлек; *сапоги с изъяном* — бу итекнең кимчелекләре бар; 2. *устар.* зыян, зарар; *нанести изъян* — зарар китерү.
**ИЗЪЯ'НИСТЫЙ** *обл.* — кимчелекле; кимчелеге булган; *изъянистый товар* — кимчелекле товар.
**ИЗЪЯСНИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж. устар.* — аңлату...-ы; аңлатып бирү...-ы; *изъяснительная работа* — аңлату эше.
**ИЗЪЯСНИ'ТЬ** *сов. книж. устар.* — аңлату, аңлатып бирү, ачыкландыру, ачыкландырып бирү, сөйләп бирү.
**ИЗЪЯСНИ'ТЬСЯ** *сов. книж. устар.* — аңлашу, сөйләшү.
**ИЗЪЯСНЯ'ТЬ** *несов. книж. устар.* — к. изъяснить.
**ИЗЪЯСНЯ'ТЬСЯ** *несов. книж. устар.* — 1. к. изъясниться; 2. *страд.* аңлатылу, аңлатып бирелү.
**ИЗЪЯ'ТЬ** *сов. книж. офиц.* — 1. алу; *изъять драгоценности из сейфов* — сейфлардан кыйммәтле әйберләрне алу; 2. кулланудан чыгару, кулланудан алу, гамәлдән чыгару; *изъять из обращения старые денежные знаки* — иске акчаларны кулланудан алу.
**ИЗЫМА'ТЬ** *несов. книж. офиц.* — к. изъять.
**ИЗЫМА'ТЬСЯ** *несов. страд., устар.*

*книж. офиц.*— кулланудан чыгарылу; кулланудан алыну.

**ИЗЫСКА'НИЕ** *ср. книж.*— 1. *(действие)* к. изыскать; 2. эзләү, тикшерү; эзләнү, тикшерену; *геологические изыскания* — геологик эзләнүләр.

**ИЗЫ'СКАННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— 1. купшылык, нәфислек; *изысканность наряда* — киемнең купшылыгы; 2. нечкәлек, нәзакәтлелек; *изысканность вкуса* — зәвыкның нечкәлеге.

**ИЗЫ'СКАННЫЙ** *книж.*— купшы, нәфис; *изысканный наряд* — купшы кием, нәфис кием. ◇ Изысканное блюдо — нәзакәтле ашамлык.

**ИЗЫСКА'ТЕЛЬ** *м. книж. спец.*— тикшеренүче, эзләнүче.

**ИЗЫСКА'ТЕЛЬСКИЙ** *книж. спец.*— тикшеренүчеләр...-ы; эзләнүчеләр ..-ы; *изыскательская партия* — тикшеренүчеләр партиясе (төркеме).

**ИЗЫСКА'ТЬ** *сов. книж. офиц.*— эзләп табу; *изыскать средства на постройку дома* — йорт салу өчен средстволар эзләп табу.

**ИЗЫСКА'ТЬСЯ** *сов. книж. офиц.*— эзләп табылу; *изыскались новые источники государственных доходов* — дәүләт доходларының яңа чыганаклары эзләп табылды.

**ИЗЫ'СКИВАТЬ** *несов. книж.*— 1. *офиц.* к. изыскать; 2. *спец.* тикшеренү, эзләнү.

**ИЗЫ'СКИВАТЬСЯ** *несов. книж.* — 1. *офиц.* к. изыскаться; 2. *страд. офиц. спец.* эзләп табылу, тикшереп табылу.

**ИЗЮ'БР** *м. зоол.*—изюбр(боланнар семьялыгыннан булган хайван).

**ИЗЮ'М** *м. мн.* нет — йөзем. ◇ Не фунт изюму *разг. шутл.*— бәрәңге ашау түгел (кечкенә нәрсә түгел мәгънәсендә).

**ИЗЮ'МИНА** *ж. разг.*— йөзем бөртеге, бер бөртек йөзем.

**ИЗЮ'МИНКА** *ж. разг.*— к. изюмина. ◇ Человек с изюминкой — дикъкатьне үзенә тартучан кеше, бик үзенчәлекле, күркәм кеше.

**ИЗЮ'МНЫЙ** *редко* — йөзем...-ы; *изюмный вкус* — йөзем тәме.

**ИЗЯ'ЩЕСТВО** *ср. мн.* нет, *книж.*— нәфислек, матурлык, зифалык, гүзәллек.

**ИЗЯ'ЩНЫЙ** *книж.*— нәфис, зифа, гүзәл, бик матур; *изящная девушка* — зифа буйлы кыз; *изящное платье* — нәфис күлмәк. ◇ Изящные искусства *устар.*— нәфис сәнгатьләр (живопись, скульптура, архитектура, музыка). Изящная литература — беллетристика, матур әдәбият.

**И'КАТЬ** *несов. лингв.*— иләштерү (мәсәлән, „е" һәм „я" авазларын „и" гә охшатып сөйләү).

**ИКА'ТЬ** *несов.*— очкылык тоту.

**ИКА'ТЬСЯ** *несов. безл. разг.*— бертуктаусыз очкылык тоту.

**ИКО'НА** *ж.*—икона, тәре, образ (христианнарда алланың һәм изгеләрнең сурәте).

**ИКОНОГРА'ФИЯ** *ж. мн.* нет, *науч.*— иконография (1. портретларны өйрәнү фәне; 2. живописьта, скульптурада, графикада, фотографиядә һ. б. билгеле бер кешенең, вакыйганың яки урынның төрлечә төшерелгән рәсемнәрен (сурәтләрен) тасвирлау һәм өйрәнү; *иконография Пушкина* — Пушкинның төрле вакытта төшерелгән рәсемнәрен, төрле вакытта ясалган скульптураларын өйрәнү).

**ИКОНОПИ'СНЫЙ** *книж.* — 1. икона ясау...-ы; *иконописная мастерская* — икона ясау (рәсемләү) мастерское; 2. *перен.* рухсыз-кырыс, җансыз; *иконописное лицо* — рухсыз-кырыс чырай.

**ИКО'РКА** *ж. мн.* нет, *разг. фам.* — к. икра I.

**ИКО'РНЫЙ** *редко* — икра...-ы; *икорная банка* — икра банкасы.

**ИКО'ТА** *ж. мн.* нет — очкылык тоту.

**ИКО'ТНИК** *м. бот.* — кыркырый, очкылык үләне.

**ИКРА'** I *ж. мн.* нет — 1. уылдык, икра; *рыбы мечут икру* — балыклар уылдык чәчә; 2. икра (үсемлек яки яшелчәне турап хәзерләнгән ашамлык); *растительная икра* — үсемлек икрасы.

**ИКРА'** II *ж. чаще мн. анат.*— балтыр, балтыр ите.

**ИКРИ'НА** *ж. разг.*— икра бөртеге, уылдык бөртеге.

**ИКРИ'СТЫЙ** I — икрага бай...; уылдыкка бай; күп икралы; күп уылдыклы; *икристая щука* — күп уылдыклы чуртан.

**ИКРИ'СТЫЙ** II *простореч. шутл.*— юан балтырлы.

**ИКРИ'ТЬСЯ** *несов. спец.*— уылдык чәчү.

**ИКРОМЕТА'НИЕ** *ср. мн.* нет, *спец.* — к. икриться.

**ИКРЯНО'Й** *спец.*— 1. икралы, уылдыклы; *икряная рыба* — икралы (уылдыклы) балык; 2. икрадан хәзерләнгән; уылдыктан хәзерләнгән; *икряной сыр* — икрадан хәзерләнгән сыр.

**ИКС** *м.*— икс (1. латин алфавитында „х" хәрефенең исеме; 2. *мат.* эзләнә торган билгесез зурлык; 3. билгесез кешегә атама). ◇ Икс-лучи *ед.* нет, *физ.*— рентген нурлары.

**ИЛ** *м. мн.* нет — ләм, лай, мәте, юшкын, дуен.

**И'ЛЕМ** *м.*— к. ильм.

**И'ЛИ** союз — 1. *(разделительный)* яки, яисә, әллә...; я, я булмаса; *ручным или машинным способом* — кул яки машина белән; *завтра или послезавтра* — иртәгә я берсекөнгә; 2. һәм; *на дне рек, озёр или морей* — елгалар, күлләр һәм диңгезләр төбендә; 3. ягъни, башкача, башкача әйткәндә; *аэроплан, или самолёт* — аэроплан, ягъни самолёт; 4. ...-мени; әллә...-ме; *или ты не слыхал об этом?* — син бу турыда ишетмәдеңмени? (әллә син бу турыда ишетмәдеңме?)

**И'ЛИСТЫЙ** — юшкынлы, ләмле, лайлы; *илистое дно* — ләмле төп (су төбе).

**ИЛЛЮЗИО'Н** *м. устар.*— к. кинематограф.

**ИЛЛЮЗИОНИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *филос.*— иллюзионизм (тышкы дөнья иллюзия генә, хыял гына дип расный торган идеалистик

философик агым; субъектив идеализмның иң чик формасы).

**ИЛЛЮЗИОНИ'СТ** *м. филос.* — иллюзионист (иллюзионизм тарафдары).

**ИЛЛЮЗИОНИСТИ'ЧЕСКИЙ** *филос.* — иллюзионистик; *иллюзионистическая философия* — иллюзионистик философия.

**ИЛЛЮЗИОНИ'СТСКИЙ** *филос.* — иллюзионистлар...-ы; иллюзионистларча...; *иллюзионистская группа* — иллюзионистлар группасы (төркеме).

**ИЛЛЮ'ЗИЯ** *ж. книж.* — иллюзия (1. тойгының алдавы нигезендә чынбарлыкны бозып күз алдына китерү; 2. *перен.* тормышка ашуы мөмкин булмаган хыял).

**ИЛЛЮЗО'РНЫЙ** *книж.* — хыялый; тормышка ашмый торган; *иллюзорные надежды* — хыялый өметләр.

**ИЛЛЮМИНА'ТОР** *м.* — иллюминатор (1. *мор.* судноларда түгәрәк тәрәзә; 2. *спец.* иллюминация эшләрен алып баручы).

**ИЛЛЮМИНА'ТЫ** *м. устар.* — иллюминатлар (Европада 18 йөзнең икенче яртысында кайбер яшерен дини-политик җәмгыятьләр исеме).

**ИЛЛЮМИНАЦИО'ННЫЙ** *спец.* — иллюминация...ы, иллюминацияләү...ы; *иллюминационные работы* — иллюминация эшләре.

**ИЛЛЮМИНА'ЦИЯ** *ж.* — иллюминация (берәр тантана, бәйрәм уңае белән урамнарны һәм йортларны төрле төстәге утлар белән яктырту).

**ИЛЛЮМИНОВА'ТЬ** *сов.* и *несов. спец.* — иллюминацияләү.

**ИЛЛЮМИНОВА'ТЬСЯ** *сов.* и *несов. страд. спец.* — иллюминацияләнү.

**ИЛЛЮСТРАТИ'ВНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — күрсәтмәлелек.

**ИЛЛЮСТРАТИ'ВНЫЙ** *книж.* — иллюстратив; күрсәтмәле; күрсәтмә...; *иллюстративный метод* — иллюстратив метод; күрсәтмәле метод; *иллюстративный материал* — күрсәтмә материал.

**ИЛЛЮСТРА'ТОР** *м. книж.* — иллюстратор (китапларны иллюстрацияләүче белгеч, художник).

**ИЛЛЮСТРА'ЦИЯ** *ж. книж.* — иллюстрация (1. *только ед.* к. иллюстрировать; 2. китапта басылган рәсемнәр; 3. күрсәтмә үрнәкләр, берәр төшенчәне яки фикерне аңлату өчен китерелгән мисаллар).

**ИЛЛЮСТРИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. книж.* — 1. иллюстрацияләү, рәсемнәр урнаштыру; 2. *перен.* күрсәтмәләр, мисаллар белән аңлату, күрсәтмә материал өстендә аңлату.

**ИЛЛЮСТРИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. страд. книж.* — 1. иллюстрацияләнү, рәсемнәр урнаштырылу; 2. күрсәтмәләр, мисаллар белән аңлатылу.

**ИЛОВА'ТЫЙ** *разг.* — ләмлерәк, юшкынлырак, лайлырак.

**ИЛО'Т** *м.* — 1. *истор.* илот (борынгы Спартада — коллык хәленә төшерелгән крестьян); 2. *перен. книж. ритор.* кол, хокуксыз, эксплуатацияләнүче.

**ИЛЬ** *союз простореч.* и *поэт.* — к. или.

**И'ЛЬКА** *ж.* — 1. *зоол.* Америка көзәне; 2. *только ед.* Америка көзәненең мехы.

**И'ЛЬКОВЫЙ** — Америка көзәне...-ы; *ильковый мех* — Америка көзәне мехы.

**ИЛЬМ** *м. бот.* — элмә (агач).

**ИЛЬМЕ'НЬ** *м. обл.* — су баса торган камышлык.

**И'ЛЬМОВЫЙ** *бот.* — элмә...-ы; *ильмовый лист* — элмә яфрагы.

**ИМАЖИНИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *лит.* — имажинизм (XX йөз башында килеп чыккан, төшенкелек белән сугарылган буржуаз әдәби юнәлеш).

**ИМАЖИНИ'СТ** *м.*, **ИМАЖИНИ'СТКА** *ж. лит.* — имажинист (имажинизм тарафдары).

**ИМАЖИНИ'СТСКИЙ** *лит.* — имажинистлар...-ы, имажинистларча...; *имажинистские взгляды* — имажинистларча карашлар.

**ИМБИ'РНЫЙ** — имбир...-ы; имбирлы; *имбирное пиво* — имбир сырасы.

**ИМБИ'РЬ** *м.* — имбир (тропик үсемлек).

**ИМЕ'НИЕ** *ср. устар.* — 1. имение (алпавыт утары); 2. *только ед.* милек.

**ИМЕНИ'НЫ** *ед.* нет — именины, исем бәйрәме (христианнарда исем кушу көне бәйрәме).

**ИМЕНИ'ТЕЛЬНЫЙ:** именительный падеж *грам.* — именительный падеж (татар теленең баш килешенә туры килә).

**ИМЕНИ'ТОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж. устар.* — атаклы кеше, танылган кеше.

**ИМЕНИ'ТЫЙ** *книж. устар.* — атаклы, танылган, исемле (исеме танылган).

**И'МЕННО** *частица* — 1. атап әйткәндә, ягъни; *лиственные деревья, а именно: дуб, берёза, осина и т. д.* — яфраклы агачлар, атап әйткәндә: имән, каен, усак һ. б.; 2. нәкъ, нәкъ үзе; *дайте мне именно эту книгу* — миңа нәкъ менә шушы китапны бирегез; 3. соң; *кто именно?* — кем соң? *сколько именно?* — күпме соң? ◇ **Вот именно** — шул-шул, шулай шул.

**ИМЕННО'Й** *книж.* — исемле, аталган, исеме куелган; *именное кольцо* — исемле йөзек. ◇ **Именное склонение** *грам.* — килеш белән төрләнеш. **Именной список** *канц.* — исемлек (исем һәм фамилияләр күрсәтелеп төзелгән исемлек).

**ИМЕНОВА'ТЬ** *несов. книж. устар.* — атау, исемләү, исем бирү, исем кушу.

**ИМЕНОВА'ТЬСЯ** *несов.* — аталу, исемләнү; *такие поступки именуются обычно преступлением* — андый эшләр гадәттә җинаять дип аталалар.

**ИМЕРЕТИ'НСКИЙ** — имеретин...-ы; *имеретинское племя* — имеретин кабиләсе.

**ИМЕРЕТИ'НЫ** *мн.* — имеретиннар, имеретин халкы (грузин кабиләләреннән берсе).

**ИМЕ'ТЬ** *несов.* — 1. ия булу, бар булу, булу, ...-лы булу; *иметь деньги* — акча булу; акчалы булу; 2. күзәтү, күрү; *за последний год в ряде капиталистических стран мы имели обострение экономического кризиса* — соңгы елда без күп кенә капиталистик илләрдә экономик кризисның

кискенләшүен күрдек; 3. *(с отрицанием)* юк, булмау; *не имею времени* — вакытым юк; *не имел времени* — вакытым булмады. ◇ **Имеет отношение** — мөнәсәбәте бар. **Имеет значение** — әһәмияте бар. **Имеет хождение** — йөри (акча турында). **Имеет намерение** — тели, уйлый. **Имеет применение** — кулланыла. **Имеет нужду** — мохтаҗ. **Имеет быть** *офиц. устар.* — булачак; *8 марта имеет быть концерт* — 8 нче мартта концерт булачак. **Иметь мужество** — батырлыгы җитү. **Иметь несчастье** — бәхетсезлеккә каршы; *он имел несчастье оступиться* — бәхетсезлегенә каршы аның аягы тайган. **Иметь место** — булу; *это событие имело место много лет тому назад* — бу вакыйга күп еллар элек булган иде. **Иметь в виду** — күздә тоту. **Иметь целью** — омтылу, максат итеп кую. **Иметь дело** — эш итү. **Иметь сердце** *(на кого)* — ачулану, ачу саклау.

**ИМЕ'ТЬСЯ** *несов.* — *(в положительной форме)* бар (булу); *имеются ли у вас новые сведения?* — сездә яңа мәгълүматлар бармы? *(в отрицательной форме)* юк; *препятствий не имеется* — каршылыклар (комачаулыклар) юк. ◇ **Иметься в виду** — күздә тотылу, күз алдында тотылу.

**ИМИТА'ТОР** *м.* — имитатор (берәр кешегә охшатып кыланучы, берәр кеше сөйләвенә охшатып сөйләүче, хайваннар, кошлар тавышына охшатып кычкыручы; *театр.* имитация белән шөгыльләнүче артист).

**ИМИТА'ТОРША** *ж.* — к. имитатор.

**ИМИТА'ЦИЯ** *ж.* — имитация (1. *(подражание)* берәр кеше сөйләвенә охшатып сөйләү; хайванnarга, кошларга охшатып кычкыру; 2. *(подделка)* охшатып ясалган әйбер; 3. *муз.* нинди дә булса бер көйне калынрак яки нәзегрәк тавыш белән кабатлау).

**ИМИТИ'РОВАТЬ** *несов.* — 1. *(подражать)* имитацияләү, охшатып сөйләү (кылану, кычкыру, сайрау); 2. *тех.* охшатып ясау, имитация эшләү; *имитировать золото* — алтынга охшатып ясау.

**ИММАНЕ'НТНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *филос.* — имманентлык (әйбернең үзенә генә хас булу).

**ИММАНЕ'НТНЫЙ** *филос.* — имманент... (әйбернең эчке табигатенә хас булган); *имманентные причины* — имманент сәбәпләр.

**ИММАТРИКУЛЯ'ЦИЯ** *ж. спец.* — исемлеккә кертү.

**ИММИГРА'НТ** *м. книж.* — иммигрант (даими тору өчен берәр илгә килеп урнашкан чит ил кешесе).

**ИММИГРА'НТКА** *ж. книж.* — к. иммигрант.

**ИММИГРА'НТСКИЙ** *книж.* — иммигрант...-ы; иммигрантлар...-ы; *иммигрантские права* — иммигрантлар хокук(лар)ы.

**ИММИГРАЦИО'ННЫЙ** *книж.* — иммиграция...-ы; *иммиграционные законы* — иммиграция законнары.

**ИММИГРА'ЦИЯ** *ж. книж.* — иммиграция (1. чит ил кешеләренең даими яшәр өчен берәр илгә күчеп килүләре; 2. *собир.* иммигрантлар).

**ИММИГРИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. книж.* — даими тору өчен чит илдән күчеп килү.

**ИММОБИЛИЗА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет — иммобилизация (1. *мед.* тәннең берәр өлешен хәрәкәтсез хәлгә китерү; 2. *экон.* оборот капиталын төп капиталга әйләндерү).

**ИММОРАЛИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *филос.* — иммрализм, әдәпсезлек, әхлаксызлык (әдәп-әхлак нормаларын танымау).

**ИММОРА'ЛЬНЫЙ** *книж.* — иммораль, әдәпсез, әхлаксыз.

**ИММУНИЗАЦИО'ННЫЙ** *спец.* — иммунизация...-ы; йогышсызландыру...-ы; *иммунизационные средства* — иммунизация чаралары.

**ИММУНИЗА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *мед.* — иммунизация (ясалма иммунитет булдыру, мәсәлән, прививка ясап); *предохранительные прививки являются обычным средством иммунизации* — саклагыч прививкалар иммунизациянең гадәттәге чарасы булып исәпләнәләр.

**ИММУНИЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.* — 1. *мед.* иммунизация ясау, организмда иммунитет булдыру; 2. *юр.* иммунитет бирү (дәүләттә аерым кешеләргә, мәсәлән, депутатларга, дипломатия вәкилләренә карата кайбер законнарны кулланмау).

**ИММУНИТЕ'Т** *м.* — иммунитет (1. *мед.* организмның йогышлы авыруларга каршы тора алучанлыгы; 2. *юр.* аерым кешеләргә, мәсәлән, дипломатия вәкилләренә карата кайбер законнарны кулланмау; *дипломатический иммунитет* — дипломатик иммунитет, ягъни дипломатия вәкиленең шәхси иминлеге һәм ул урнашкан бинаның иминлеге).

**ИММУ'ННЫЙ** *книж. мед.* — иммунитетлы; агуга каршы тора алучан; *ёж иммунен к яду гадюки* — керпенең организмы кара елан агуына каршы тора ала.

**ИМПЕРАТИ'В** *м. книж.* — императив (1. *филос.* катгый таләп; 2. *грам.* боерык фигыль).

**ИМПЕРАТИ'ВНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — императивлык (катгый рәвештә таләп итүчәнлек).

**ИМПЕРАТИ'ВНЫЙ** *книж. филос.* — императив (һичбер шартсыз буйсынучы, үтәүне катгый рәвештә таләп итә торган). ◇ **Императивный мандат** *офиц.* — императив мандат (билгеле бер эшләрне генә башкарырга кушып бирелгән язма наказ).

**ИМПЕРА'ТОР** *м. истор.* — император (1. монархларның иң югары титулы; шул титул бирелгән монарх; 2. борынгы Римда — югары гаскәр башлыгы).

**ИМПЕРА'ТОРСКИЙ** — император...-ы; императорлык...-ы; *императорский указ* — император указы; *императорский титул* — императорлык титулы, император титулы.

**ИМПЕРА'ТОРСТВО** *ср. мн.* нет — императорлык.

**ИМПЕРАТРИ'ЦА** *ж.* — к. император 1.

**ИМПЕРИА'Л** *м. истор.* — империал (1. Россиядә алтын акча; башта 10 сумлык, 1897 елдан соң 15 сумлык; 2. пассажирлар йөртә торган ике катлы конкаларның һәм омнибусларның өске каты).

**ИМПЕРИАЛИ'ЗМ** *м. мн.* нет — империализм (1. капитализмның югарыгы һәм иң соңгы стадиясе; империализм эре монополияләрнең хакимлек итүе белән, эре капиталистик илләрнең чимал чыганаклары өчен, товар урнаштыру базарлары өчен, чит территорияләрне яулап алып, чит халыкларны эксплуатацияләү өчен ерткычларча көрәшүләре белән характерлана; бу көрәш инде бүленеп беткән дөньяны яңадан бүлү сугышларын китереп чыгара; 2. *полит.* чит илләрне басып алу политикасы).

**ИМПЕРИАЛИ'СТ** *м.* — империалист (империализм политикасын үткәрүче эре капиталист, демократиянең һәм прогрессның дошманы).

**ИМПЕРИАЛИСТИ'ЧЕСКИЙ** и **ИМПЕРИАЛИ'СТСКИЙ** — империалистик, империалистлар...-ы; *империалистическая война* — империалистик сугыш.

**ИМПЕ'РИЯ** *ж. истор.* — империя (1. башында император торган монархистик дәүләт; 2. агрессив политика алып бара һәм колония халыкларын аяусыз рәвештә эксплуатацияли торган эре империалистик дәүләт).

**ИМПЕ'РСКИЙ** — империя...-ы; империя карамагындагы; *имперская армия* — империя армиясе.

**ИМПОЗА'НТНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — мәһабәтлек, күркәмлек, сөйкемлелек, импозантлык.

**ИМПОЗА'НТНЫЙ** *книж.* — мәһабәт, күркәм, сөйкемле; импозант; *у него импозантная фигура* — ул мәһабәт гәүдәле.

**ИМПОНИ'РОВАТЬ** *несов. книж.* — яхшы караш тудыру, үзенә җәлеп итү, үзенә карату, хөрмәт казану.

**И'МПОРТ** *м. экон.* — импорт (чит илләрдән товар кертү).

**ИМПОРТЁР** *м. экон.* — импортёр (чит илләрдән товар кертүче).

**ИМПОРТИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. экон.* — чит илләрдән товар кертү.

**ИМПОРТИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. экон.* — чит илләрдән товар кертелү.

**И'МПОРТНЫЙ** *экон.* — импорт...-ы; чит ил(ләр)дән кертелгән; *импортный товар* — импорт товары, чит ил(ләр)дән кертелгән товар.

**ИМПОТЕ'НТ** *м. мед.* — импотент (җенси көчсезлек белән авыручы кеше).

**ИМПОТЕ'НТНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — импотентлык, җенси көчсезлек.

**ИМПОТЕ'НТНЫЙ** — 1. *мед.* импотент...; җенси көчсез; *импотентный человек* — импотент кеше, җенси көчсез кеше; 2. *перен. книж. пренебр.* импотент..., көчсез, зәгыйфь; *импотентная мысль* — импотент фикер, көчсез фикер, зәгыйфь фикер.

**ИМПОТЕ'НЦИЯ** *ж. мн.* нет — импотенция (1. *мед.* ирләрдә булган җенси көчсезлек һәм шуңа бәйләнгән авыру; 2. *перен. пренебр.* рухи көчсезлек).

**ИМПРЕССА'РИО** *м. нескл. театр.* — к. антрепренёр.

**ИМПРЕССИОНИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *искус.* — импрессионизм (сәнгатьтә һәм әдәбиятта XIX йөзнең икенче яртысында барлыкка килгән индивидуалистик юнәлеш; төшенкелек, иҗтимагый мәсьәләләрдән читләшү, эчтәлеккә зарар китереп форма белән мавыгу бу юнәлешнең характерлы яклары булып тора).

**ИМПРЕССИОНИ'СТ** *м. искус.* — импрессионист, импрессионизм тарафдары (художник, музыкант, язучы).

**ИМПРЕССИОНИСТИ'ЧЕСКИЙ** *искус.* — импрессионистик; *импрессионистическая музыка* — импрессионистик музыка.

**ИМПРЕССИОНИ'СТКА** *ж. искус.* — к. импрессионист.

**ИМПРЕССИОНИ'СТСКИЙ** *искус.* — импрессионистлар...-ы; импрессионистларча...; импрессионистларга хас; *импрессионистская манера игры* — уенның импрессионистларга хас манеры.

**ИМПРОВИЗА'ТОР** *м. книж.* — импровизатор (импровизация ясарга сәләтле кеше).

**ИМПРОВИЗА'ТОРСКИЙ** *книж.* — импровизаторлык...-ы; *импровизаторский талант* — импровизаторлык таланты.

**ИМПРОВИЗА'ТОРСТВО** *ср. мн.* нет, *книж.* — импровизаторлык.

**ИМПРОВИЗА'ЦИЯ** *ж. книж.* — импровизация (алдан хәзерләнмичә, башкару моментында гына уйлап, шигырь яки көй чыгару; шулай чыгарылган шигырь яки көй).

**ИМПРОВИЗИ'РОВАТЬ** *несов. книж.* — 1. импровизацияләү, импровизация ясау (алдан хәзерләнмичә шигырь яки көй чыгару); 2. *ирон.* башка ни килсә шуны сөйләү, үзеннән уйлап чыгару; 3. *перен. разг. шутл.* тиз генә эшләп ташлау, хәзерлексез эшләп ташлау.

**И'МПУЛЬС** *м. книж.* — импульс (1. нинди дә булса эшкә дәртләндерүче сәбәп, көч; 2. *физиол.* нерв уяткычларының эшчәнлеге аркасында барлыкка килеп ирексездән эшләнә торган хәрәкәт).

**ИМПУЛЬСИ'ВНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — импульсивлык.

**ИМПУЛЬСИ'ВНЫЙ** *книж. физиол.* — 1. импульсив; хәрәкәтчән (тәэсир булгач ук хәрәкәт итәргә тора торган); *импульсивный человек* — импульсив кеше, хәрәкәтчән кеше; 2. импульсив; ирексез эшләнгән; *импульсивные действия* — импульсив хәрәкәтләр, ирексез эшләнгән хәрәкәтләр.

**ИМУ'ЩЕСТВЕННЫЙ** *офиц.* — милек...-ы; милеккә бәйләнгән; *имущественные отношения* — милеккә бәйләнгән мөнәсәбәтләр.

**ИМУ'ЩЕСТВО** *ср. мн.* нет — 1. милек, мал-мөлкәт; *государственное имущество* — дәүләт милке; 2. байлык, кирәк-ярак; *стол, стул да кровать — всё моё имущество* — өстәл, урындык һәм кровать — минем бөтен байлыгым.

**ИМУ'ЩИЙ** *устар.* — мал-мөлкәтле, хәл-

ле, бай; *имущие классы* — бай сыйныфлар. ◇ **Власть имущие** *офиц. устар. теперь ирон.* — идарә итүчеләр, власть башында торучылар.

**И'МЯ** *ср.* — 1. исем, ат; *моё имя Даут* — минем исемем Даут; 2. исем, дан, шөһрәт; *человек с именем* — шөһрәтле кеше; 3. *перен.* атказанган кеше, дан алган кеше; *советская наука насчитывает немало крупных имён* — совет фәне өлкәсендә дан алган кешеләр аз түгел. ◇ **Имя существительное** *лингв.* — исем. **Имя прилагательное** *лингв.* — сыйфат. **Имя числительное** *лингв.* — сан. **Во имя** *(кого-чего)* — хакына; *во имя дружбы* — дуслык хакына; *во имя освобождения родной земли* — туган илне азат итү хакына. **От имени** *(кого)* — исеменнән; *скажите ему от моего имени* — минем исемемнән әйтегез аңа. **На имя** *(кого)*—исеменә; *заявление написано на имя директора завода* — гариза завод директоры исеменә язылган. **Только по имени** — исеме генә, исеме буенча гына (формаль яктан гына, тышкы яктан гына); *он начальник только по имени* — аның исеме генә начальник, ул формаль яктан гына начальник. **Именем** *(кого-чего)* — исеменнән, нигезендә; *именем закона* — закон исеменнән (нигезендә). **Имени** *(кого-чего)* — исемендәге; *Волго-Донской канал имени В. И. Ленина* — В. И. Ленин исемендәге Волга-Дон каналы.

**ИМЯРЕ'К** *м. шутл. устар.* — кемдер, фәлән.

**ИН** *частица, обл.* — я, ярый; *ин, быть по-твоему* — я, ярый, синеңчә булсын.

**ИНАКОМЫ'СЛЯЩИЙ** *книж. ирон.* — башкача уйлый торган, икенче төрле фикер йөртә торган, башкача уйлаучы, башкача фикерләүче.

**И'НА'ЧЕ** — 1. *нареч.* башкача, бүтәнчә, икенче төрле, башка төрле; *сделать иначе* — башкача эшләргә; икенче төрле эшләргә; 2. *союз* югыйсә; *бегите, иначе опоздаете* — йөгерегез, югыйсә кичегерсез. ◇ **Так или иначе** *разг.* — ничек булса да, ничек кенә булмасын, алаймы-болаймы, тегеләйме-болаймы; *так или иначе я должен уехать* — ничек кенә булмасын, мин китәргә тиешмен.

**ИНБИ'РНЫЙ, ИНБИ'РЬ** — к. имбирный, имбирь.

**ИНВАЛИ'Д** *м.* — 1. инвалид, гарип (картлык яки авыру сәбәпле хезмәткә яраклылыгын югалткан кеше; сугышта яраланып гарипләнгән, имгәнгән кеше); 2. *перен. разг.* гарип, җимерек, ватык (озак файдаланудан ватылып, җимерелеп, тишелеп беткән әйбер).

**ИНВАЛИ'ДНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *разг.* — 1. инвалидлык, гариплек; *надо перевести этого рабочего на инвалидность* — бу эшчене инвалидлыкка чыгарырга кирәк; 2. *офиц.* хезмәткә яраксызлык; *размер пособия определяется степенью инвалидности* — пособиянең күләме хезмәткә яраксызлык дәрәҗәсенә карап билгеләнә.

**ИНВАЛИ'ДНЫЙ** — 1. инвалидлар...-ы; гарипләр...-ы; *инвалидный дом* — инвалидлар йорты; 2. йончыган; *у него совсем инвалидный вид* — ул бик йончыган кыяфәтле.

**ИНВЕКТИ'ВА** *ж. книж.* — инвектива (берәр кешегә каршы кискен чыгыш; мәсхәрәләп сөйләү, дошманлык чыгышы).

**ИНВЕНТАРИЗА'ЦИЯ** *ж. офиц.* — инвентаризация, инвентарь исемлегенә кертү (1. берәр оешма, предприятие яки хуҗалык милегенең исемлеген төзү; 2. яңа милекне исемлеккә кертү).

**ИНВЕНТАРИЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. офиц.* — инвентаризация ясау.

**ИНВЕНТАРИЗОВА'ТЬ** *сов.* и *несов. офиц.* — к. инвентаризировать.

**ИНВЕНТА'РНЫЙ** *офиц.* — инвентарь...-ы; *инвентарная книга* — инвентарь кенәгәсе.

**ИНВЕНТА'РЬ** *м.* — 1. инвентарь; *сельскохозяйственный инвентарь* — авыл хуҗалыгы инвентаре; *живой инвентарь* — җанлы инвентарь (терлек); *мёртвый инвентарь* — җансыз инвентарь (кораллар, машиналар, һәртөрле җиһазлар); 2. *офиц.* исемлек, опись.

**ИНВЕРСИ'РОВАННЫЙ** *лингв. лит.* — инверсияләнгән; инверсияле; *инверсированный порядок слов* — сүзләрнең инверсияләнгән тәртибе; *инверсированная речь* — инверсияле сөйләм.

**ИНВЕ'РСИЯ** *ж. лингв. лит.* — инверсия (мәгънәгә оттенок бирү яки стиль үзенчәлеге кертү өчен җөмләдәге сүзләрнең гадәттәге тәртибен үзгәртү).

**ИНВЕСТИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. экон.* — берәр предприятиегә капитал салу.

**ИНВЕСТИ'ТОР** *м. экон.* — инвеститор (нинди дә булса бер предприятиегә капитал салучы).

**ИНВЕСТИ'ЦИЯ** *ж. экон.* — инвестиция (1. берәр предприятиегә капитал салу; 2. салынган капитал).

**ИНВОЛЮЦИО'ННЫЙ** *биол.* — инволюция ...-ы; элекке хәленә кайту...-ы; *инволюционный процесс* — инволюция процессы, элекке хәленә кайту процессы.

**ИНВОЛЮ'ЦИЯ** *ж. биол. физиол.* — инволюция, элекке хәлгә кайту (берәр сәбәп аркасында зурайган органның элекке хәленә кайтуы).

**ИНГАЛЯ'ТОР** *м. мед.* — ингалятор (ингаляция аппараты).

**ИНГАЛЯЦИО'ННЫЙ** *мед.* — ингаляция ...-ы; *ингаляционный прибор* — ингаляция приборы.

**ИНГАЛЯ'ЦИЯ** *ж. мед.* — ингаляция (парларны, газларны, пар хәленә китерелгән сыекчаларны эчкә сулату юлы белән дәвалау).

**ИНГРЕДИЕ'НТ** *м. науч.* — ингредиент (нинди дә булса катлаулы матдәнең состав өлеше).

**И'НДЕВЕТЬ** *несов. обл.* — бәсәрү, бәсләнү, сыкылау.

**ИНДЕ'ИЧИЙ** *обл.* — күркә ...-ы; *индеичьи потроха* — күркә эч-бавырлары, күркә баш-аягы.

**ИНДЕ'ЙКА** *ж.* — 1. *обл.* ана күркә; 2. күркә ите.

**ИНДЕ'ЙСКИЙ** — индеец...-ы; индеецлар ...-ы; *индейский костюм* — индеецлар костюмы. ◇ **Индейский петух** *разг.* — ата күркә.

**ИНДЕ'ЙЦЫ** *мн.* — индеецлар (Америкадагы төп җирле халыкның гомуми исеме).

**И'НДЕКС** *м. книж.* — индекс (1. нинди дә булса исемлек, белешмә, белешмә кенәгәсе; 2. *антр.* тәннең төрле өлешләре арасындагы мөнәсәбәтне күрсәткән цифрлар тезмәсе; *индекс физического развития* — физик үсешнең индексы; 3. *экон.* нинди дә булса экономик күренешнең әзлекле рәвештә үзгәрә баруын процентларда күрсәтә торган цифрлы күрсәткеч; 4. *спец.* цифрларның яки хәрефләрнең уң яклары на куела торган сан яки хәреф күрсәткечләр, мәсәлән, $A_2$, 1°).

**ИНДЕКСНЫЙ** *книж. спец.* — индекс...-ы; *индексные показания* — индекс күрсәткечләре (к. индекс 2. 3, 4).

**ИНДЕТЕРМИНИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *филос.* — индетерминизм (табигать һәм җәмгыятьтәге күренешләр арасында сәбәп бәйләнешләре һәм гомуми закончалык барлыгын инкарь итә торган идеалистик юнәлеш).

**ИНДЕТЕРМИНИ'СТ** *м. филос.* — индетерминист, индетерминизм тарафдары.

**ИНДЕТЕРМИНИСТИ'ЧЕСКИЙ** *филос.* — индетерминистик, индетерминистларча...; *индетерминистическое толкование общественных явлений* — җәмгыять күренешләрен индетерминистларча аңлату; *индетерминистический взгляд* — индетерминистик караш.

**ИНДИАНИ'СТ** *м.* — индианист (һинд телләре галиме).

**ИНДИАНИ'СТИКА** *ж. мн.* нет — индианистика, һинд телләрен өйрәнү.

**ИНДИВИ'Д** *м. книж.* — к. индивидуум.

**ИНДИВИДУА'Л** *м.* — индивидуал (берәр эшне ялгыз башкаручы).

**ИНДИВИДУАЛИЗА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет — к. индивидуализировать һәм индивидуализироваться.

**ИНДИВИДУАЛИЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. книж.* — индивидуализация ясау, индивидуальләштерү (предметны, шәхесне үзенә генә хас булган билгеләр буенча аерып алу).

**ИНДИВИДУАЛИЗИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. страд. книж.* — индивидуализация ясалу, индивидуальләштерелү.

**ИНДИВИДУАЛИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *филос.* — индивидуализм (1. шәхси интересларны җәмгыять интересларыннан өстен күрүче буржуаз караш; 2. иҗтимагый күренешләрне халыкларның, массаларның, сыйныфларның эшчәнлеге нәтиҗәсе дип түгел, бәлки аерым шәхесләрнең эшчәнлеге нәтиҗәсе дип аңлатучы идеалистик юнәлеш).

**ИНДИВИДУАЛИ'СТ** *м. книж.* — индивидуалист, индивидуализм тарафдары.

**ИНДИВИДУАЛИСТИ'ЧЕСКИЙ** *книж.* — индивидуалистик, индивидуалистларча...; *индивидуалистическая философия* — индивидуалистик философия; *индивидуалистический подход к делу* — эшкә индивидуалистларча мөнәсәбәт.

**ИНДИВИДУАЛИ'СТКА** *ж. книж.* — к. индивидуалист.

**ИНДИВИДУАЛИ'СТСКИЙ** *книж.* — индивидуалистларча...; индивидуалистларга хас; *индивидуалистские замашки* — индивидуалистларча кыланышлар.

**ИНДИВИДУА'ЛЬНОСТЬ** *ж. книж.* — 1. индивидуальлек (а. үзенә бер төрлелек; б. бер шәхесне икенче шәхестән аера торган индивидуаль үзенчәлекләр); 2. аерым шәхес.

**ИНДИВИДУА'ЛЬНЫЙ** — 1. *книж.* индивидуаль, шәхескә хас; шәхси; *индивидуальные особенности* — индивидуаль (шәхси) үзенчәлекләр; 2. *офиц.* индивидуаль; аерым; ялгыз; *индивидуальное хозяйство* — ялгыз хуҗалык; 3. индивидуаль; аерым-аерым; *индивидуальное обслуживание* — индивидуаль хезмәт күрсәтү; 4. *спец.* (*предназначенный для одного*) һәркем өчен аерым.

**ИНДИВИ'ДУУМ** *м.* — 1. индивидуум, аерым кеше, шәхес, зат; 2. *биол.* индивидуум (мөстәкыйль яши торган һәрбер тере организм); 3. *разг. шутл.* билгесез кеше.

**ИНДИ'ГО** *ср. нескл.* — индиго (1. кыйммәтле карасу-зәңгәр буяу; 2. шул буяу алына торган үсемлек).

**ИНДИ'ЙСКИЙ** — Һиндстан...-ы; һинд...-ы; *индийское правительство* — Һиндстан хөкүмәте; *индийское отделение* — һинд бүлеге.

**ИНДИ'ЙЦЫ** *мн.* — һиндстанлылар, һинд халкы.

**ИНДИКА'ТОР** *м.* — индикатор (1. *тех.* пешкәкле (поршеньлы) машиналарның цилиндрларындагы басым үзгәрешләрен үлчи торган аппарат; 2. *хим.* нинди дә булса химик процессның үзенчәлеген күрсәтә торган матдә).

**ИНДИКА'ТОРНЫЙ** *тех.* — индикатор ...-ы; *индикаторная диаграмма* — индикатор диаграммасы.

**ИНДИ'КТ** *м. истор.* — индикт (борынгы заманда еллар санын исәпләү бирәмлеге; 15 елга туры килә торган бу бирәмлек чиркәүләрдә кулланылган).

**ИНДИФФЕРЕНТИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *книж.* — индифферентизм, илтифатсыз мөнәсәбәт, салкын караш, әһәмият бирмәү, игътибарсызлык.

**ИНДИФФЕРЕ'НТНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — индифферентлык, илтифатсызлык, игътибарсызлык, салкын карау, барыбер дип карау.

**ИНДИФФЕРЕ'НТНЫЙ** *книж.* — индифферент, игътибарсыз, илтифатсыз; салкын; *индифферентное отношение* — индифферент мөнәсәбәт, илтифатсыз мөнәсәбәт.

**И'НДО** (или йнда) *союз обл.* — хәтта; *ударился лбом, индо искры из глаз посыпались* — маңгаем белән шул кадәр каты бәрелдем, хәтта күземнән утлар күренде.

**ИНДОГЕРМА'НСКИЙ** *лингв.* — к. индоевропейский.

**ИНДОЕВРОПЕИ'СТ** *м. лингв.* — индо-

европеист (һинд-европа телләрен өйрәнүче галим).

**ИНДОЕВРОПЕИ'СТИКА** *ж. лингв.* — индоевропеистика (һинд-европа телләрен өйрәнә торган фән).

**ИНДОЕВРОПЕ'ЙСКИЙ** — һинд-европалылар...-ы; һинд-европа...-ы; *индоевропейские языки* — һинд-европа телләре.

**ИНДОЕВРОПЕ'ЙЦЫ** *мн.* — һинд-европалылар (һинд-европа телләрендә сөйләшүче халыклар).

**ИНДОНЕЗИ'ЙЦЫ** *мн.* — индонезияләр, Индонезия халкы.

**ИНДУИ'ЗМ** *м. мн.* нет — индуизм (һиндстанлылар арасында иң күп таралган дин).

**ИНДУКТИВИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *филос.* — индуктивизм (фикер йөртүдә индукция методын дедукция методыннан өстен санау).

**ИНДУКТИ'ВНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж. спец.* — индуктивлык; *индуктивность доказательств* — дәлилләрнең индуктивлыгы.

**ИНДУКТИ'ВНЫЙ** *книж.* — 1. *филос.* индуктив; индукциягә нигезләнгән; *индуктивное доказательство* — индуктив исбат итү (дәлил китерү); 2. *физ.* индукция...-ы; *индуктивное сопротивление* — индукция каршылыгы.

**ИНДУ'КТОР** *м. физ.* — индуктор (1. алмаш токлы кечкенә генә магнето — электрик машина; телефонда абонентны яки станцияне тоташтыру өчен кулланыла; 2. электрик генераторда, динамомашинада магнит кыры булдыра торган электромагнит).

**ИНДУКТО'РИЙ** *м. физ.* — к. индуктор.

**ИНДУ'КТОРНЫЙ** *физ.* — индуктор ...-ы; *индукторная катушка* — индуктор кәтүге.

**ИНДУКЦИО'ННЫЙ** *физ.* — индукцион, индукция...-ы; *индукционный ток* — индукцион ток (индукция нәтиҗәсендә барлыкка килгән ток).

**ИНДУ'КЦИЯ** *ж.* — индукция (1. *филос.* аерым фактларга нигезләп гомуми нәтиҗә чыгару методы; индуктив метод; 2. *физ.* нинди дә булса үткәргечне магнит кырында хәрәкәт иттергәндә шул үткәргечтә электр тогы барлыкка килү).

**ИНДУСТРИАЛИЗА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *экон.* — индустриализация, индустрияләштерү, индустрияләштерелү (индустриаль машина техникасына күчү, күчерү, күчерелү); *индустриализация страны* — илне индустрияләштерү.

**ИНДУСТРИАЛИЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. экон.* — индустрияләштерү.

**ИНДУСТРИАЛИЗИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. страд. экон.* — индустрияләштерелү.

**ИНДУСТРИАЛИЗОВА'ТЬ** *сов.* и *несов. экон.* — к. индустриализировать.

**ИНДУСТРИАЛИЗОВА'ТЬСЯ** *сов.* и *несов. экон.* — к. индустриализироваться.

**ИНДУСТРИА'ЛЬНЫЙ** *экон.* — индустриаль; *индустриальные страны* — индустриаль илләр.

**ИНДУ'СТРИЯ** *ж. мн.* нет, *экон.* — индустрия, промышленность; *лёгкая индустрия* — җиңел индустрия (җиңел промышленность); *тяжёлая индустрия* — авыр индустрия (авыр промышленность).

**ИНДУ'СЫ** *мн.* — индуслар (индуизм динен тотучы һиндлеләр).

**ИНДЮ'К** *м.* — күркә; ата күркә.

**ИНДЮ'ШЕЧИЙ** *разг.* — күркә...-ы; *индюшечьи яйца* — күркә йомыркалары.

**ИНДЮ'ШКА** *ж.* — 1. ана күркә; 2. *обл.* күркә ите.

**ИНДЮШО'НОК** (*мн.* индюшата) *м. разг.* — күркә баласы.

**И'НЕЙ** *м. мн.* нет — бәс, сыкы.

**ИНЕ'РТНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — сүлпәнлек, дәртсезлек, инициативасызлык.

**ИНЕ'РТНЫЙ** *книж.* — 1. *физ.* инерцияле (баштагы хәлдә булган тынычлыкны яки бер төрле хәрәкәтне саклаучы); 2. *перен.* дәртсез, сүлпән, инициативасыз.

**ИНЕ'РЦИЯ** *ж. мн.* нет — 1. *физ.* инерция (баштагы тынычлык хәлен яки хәрәкәт юнәлешен һәм тизлеген саклау үзлеге); 2. *перен.* дәртсезлек, сүлпәнлек, хәрәкәтсезлек, инициативасызлык. ◇ **По инерции** *разг. перен.* — гадәт буенча, аңсыз рәвештә.

**ИНЖЕ'КТОР** *м. тех.* — инжектор (пар басымы белән пар казанына су кертү яки чыгару приборы).

**ИНЖЕНЕ'Р** *м.* — инженер (югары техник белем алган белгеч).

**ИНЖЕНЕ'РИЯ** *ж. мн.* нет, *книж.* — 1. инженерлык сәнгате, инженерлык эше; 2. *собир. разг.* инженерлар.

**ИНЖЕНЕ'РНЫЙ** *спец.* — инженерлык ...-ы, инженерлар...-ы; *инженерные войска* — инженерлык гаскәрләре; *инженерное управление* — инженерлар идарәсе.

**ИНЖЕНЕ'РСКИЙ** — инженерлык ...-ы; *инженерские обязанности* — инженерлык вазифалары.

**ИНЖЕНЕ'РСТВО** *ср. мн.* нет — 1. инженерлык профессиясе; 2. *собир.* инженерлар; *советское инженерство* — совет инженерлары.

**ИНЖЕНЕ'РША** *ж. разг.* — инженер хатыны.

**ИНЖЕНЮ'** *ж. театр.* — инженю (тәҗрибәсез, беркатлы яшь кыз ролен уйнаучы артистка).

**ИНЖИ'Р** *м. бот.* — инҗир (агачы һәм җимеше).

**ИНЖИ'РНЫЙ** — инҗир...-ы; инҗирдән хәзерләнгән; *инжирное варенье* — инҗир вареньесы; *инжирное кофе* — инҗирдән хәзерләнгән кофе.

**И'НИСТЫЙ** — бәсле, бәсәргән, бәсләнгән, сыкылы.

**ИНИЦИА'Л** *м.* — инициал (кешенең үз исеменең һәм әтисе исеменең баш хәрефләре); *инициалы А. В., а фамилия — Иванов* — инициаллары А. В., ә фамилиясе — Иванов.

**ИНИЦИАТИ'ВА** *ж. книж.* — инициатива (1. берәр эшне башлап җибәрү; 2. берәр эштә җитәкчелек роле).

**ИНИЦИАТИ'ВНЫЙ** *книж.* — 1. инициа-

тивалы; *он инициативный человек* — ул инициативалы кеше; 2. инициаторлар...-ы; башлап җибәрүчеләр...-ы; *инициативная группа* — инициаторлар группасы.

**ИНИЦИА'ТОР** *м. книж.* — инициатор (берәр яңа эшне башлап җибәрүче).

**ИНИЦИА'ТОРСКИЙ** *книж.* — инициатор...-ы; инициаторлар...-ы; инициаторларча; *инициаторский подход к делу* — эшкә инициаторларча мөнәсәбәт.

**ИНИЦИА'ТОРСТВО** *ср. мн.* нет, *книж.* — инициаторлык, инициатива күрсәтү.

**ИНИЦИА'ТОРША** *ж. разг.* — к. инициатор.

**ИНКАССА'ТОР** *м. банк.* — инкассатор (инкассо эшләрен башкаручы кеше).

**ИНКАССА'ТОРСКИЙ** *банк.* — инкассатор...-ы; *инкассаторские обязанности* — инкассатор вазифалары.

**ИНКАССА'ЦИЯ** *ж. банк.* — инкассация (инкассо эшләрен башкару).

**ИНКАССИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. банк.* — инкассировать итү (инкассо эшләрен башкару; тиешле документ буенча акча алу).

**ИНКА'ССО** *ср. нескл. банк.* — инкассо (учреждение яки берәр кешенең тапшыруы буенча вексель яки башка документ белән акча алу).

**ИН-КВА'РТО** *тип.* — 1. *нареч. (в четвёрку)* кәгазь битенең дүрттән бере зурлыгында, кәгазь битенең чиреге зурлыгында; *книга напечатана ин-кварто* — китап кәгазь битенең дүрттән бере зурлыгында басылган; 2. *нескл. в знач. прил.* кәгазь битенең дүрттән бере зурлыгындагы, кәгазь битенең чиреге зурлыгындагы; *книга ин-кварто* — кәгазь битенең дүрттән бере зурлыгындагы китап.

**ИНКВИЗИ'ТОР** *м.* — инквизитор (1. *истор.* инквизиция члены; 2. *перен.* газаплаучы, җәфалаучы, кансыз кеше).

**ИНКВИЗИ'ТОРСКИЙ** — 1. *истор.* инквизитор...-ы; инквизиторлар...-ы; инквизиторлык...-ы; *инквизиторский допрос* — инквизитор допросы; *инквизиторский тон* — инквизитор тоны; 2. *перен. книж.* инквизиторларча...; шикләнеп сынаучан, аяусыз каты; *инквизиторский взгляд* — инквизиторларча караш.

**ИНКВИЗИ'ТОРСТВО** *ср. мн.* нет, *книж.* — инквизиторлык, аяусыз катылык, рухи газаплау.

**ИНКВИЗИЦИО'ННЫЙ** *истор.* — инквизиция...-ы; *инквизиционный суд* — инквизиция суды.

**ИНКВИЗИ'ЦИЯ** *ж. мн.* нет — 1. *истор.* инквизиция (Көнбатыш Европада 13 гасыр башында дин дошманнарына каршы көрәшү өчен католик дине тарафыннан оештырылган һәм үзенең ерткычлыклары белән танылган хөкем итү һәм җәзалау оешмасы); 2. *перен.* (*пытка*) аяусыз каты җәзалау, газаплау, җәфалау.

**ИНКО'ГНИТО** *книж. нареч.* — инкогнито, яшертен, яшерен исем астында, үз исемен яшереп, уйдырма исем белән, уйдырма исем астында; *путешествовать инкогнито* — яшерен исем астында сәяхәт итү, инкогнито сәяхәт итү.

**ИНКОРПОРА'ЦИЯ** *ж. книж.* — инкорпорация (1. *науч.* берәр әйбернең составына кертү; 2. *полит.* мөстәкыйль яшәп килгән берәр территорияне яки илне берәр дәүләткә кушу; 3. *юр.* төрле вакытларда чыгарылган закон актларын берләштерү).

**ИНКОРПОРИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. книж.* — инкорпорация ясау, үз составына кертү, үзенә кушу.

**ИНКОРПОРИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. книж.* — инкорпорацияләнү, . . . составына кертелү, кушылу.

**ИНКРИМИНИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. юр.* — җинаятьтә гаепләү.

**ИНКРИМИНИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. юр.* — җинаятьтә гаепләнү.

**ИНКРУСТА'ЦИЯ** *ж. спец.* — инкрустация (1. агач, сөяк яки таш әйберләргә кыйммәтле материалдан кисеп урнаштырылган бизәкләр; *табакерка с золотой инкрустацией* — алтын бизәкләр белән бизәлгән тәмәке савыты; 2. *только ед.* инкрустация белән шөгыльләнү).

**ИНКРУСТИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. спец.* — инкрустация белән бизәү.

**ИНКУБА'ТОР** *м. спец.* — инкубатор (ясалма җылылык ярдәме белән йомыркалардан чебеш чыгару аппараты).

**ИНКУБАТО'РИЙ** *м. спец.* — инкубаторий (инкубаторлар өчен хәзерләнгән махсус бина).

**ИНКУБА'ТОРНЫЙ** *спец.* — инкубатор ...-ы; *инкубаторное хозяйство* — инкубатор хуҗалыгы.

**ИНКУБАЦИО'ННЫЙ** *спец.* — инкубация ...-ы; *инкубационные работы* — инкубация эшләре; *инкубационный период* — инкубация чоры.

**ИНКУБА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет — инкубация (1. инкубаторда чебешләр чыгару; 2. *мед.* йогышлы авыруның йоккан вакытыннан алып беренче билгеләре күренә башлаганга кадәр булган вакыт).

**ИНКУБИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. спец.* — инкубацияләү, инкубаторда җылыту (чебеш чыгару өчен йомыркаларны).

**ИНКУБИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. спец.* — инкубаторда җылытылу (чебеш чыгару өчен).

**ИНКУНА'БУЛЫ** *мн. лит., спец.* — инкунабуллар (Көнбатыш Европада типография хәрефләре белән җыелып ин беренче басылган китаплар).

**ИНОБЫТИЕ'** *ср. мн.* нет, *филос.* — яшәешнең башка формасы (берәр әйбернең үз яшәешеннән башка формасы, чит формасы).

**ИНОВЕ'РЕЦ** *м.*, **ИНОВЕ'РКА** *ж. книж.* — башка диндәге кеше.

**ИНОГДА'** *нареч.* — кайчак, кайчакта, кайбер чакта, вакыт-вакыт, ара-тирә, кайвакыт, кайбер очракларда; *он иногда заходит к нам* — ул безгә ара-тирә кергәли.

**ИНОГОРО'ДНИЙ** и **ИНОГОРО'ДНЫЙ** *офиц.* — 1. бүтән шәһәрдәге, бүтән шәһәрдә торучы; бүтән шәһәргә җибәрелә тор-

ган, читкә җибәреләә торган; 2. *устар.* казачилар сословиесенә керми торган крестьян (казачилар яши торган өлкәләрдә).

**ИНОЗЕ'МЕЦ** *м. устар.* — к. иностранец.

**ИНОЗЕ'МКА** *ж. устар.* — к. иноземец.

**ИНОЗЕ'МНЫЙ** *устар.* — к. иностранный.

**ИНОЗЕ'МЩИНА** *ж. мн.* нет, *разг. устар.* — к. иностранщина.

**ИНО'Й** — 1. башка, бүтән, икенче; *никто иной этого сделать не сумеет* — башка беркем дә моны эшләргә булдыра алмас; 2. кайбер, кайсыбер, нинди дә булса, ниндидер; *в ином случае это бывает и невозможно сделать* — кайбер очракларда моны эшләргә мөмкин дә булмый; 3. бер, берәү, беренче, икенче һ. б.; *иному человеку жарко, иному холодно* — бер кешегә эссе, ә икенчесенә салкын; *иному нравится, иному нет* — берәүгә ошый, икенчегә ошамый. ◇ **Иной раз** — кайбер вакыт, кайчакта. **Тот или иной** — теге я бу.

**И'НОК** *м. церк. книж.* — монах.

**И'НОКИНЯ** *ж. церк. книж.* — к. монахиня.

**ИН-ОКТА'ВО** *нареч. тип.* — 1. кәгазь битенең сигездән бере зурлыгында; *книга напечатана ин-октаво* — китап кәгазь битенең сигездән бере зурлыгында басылган; 2. *в знач. нескл. прил.* кәгазь битенең сигездән бере зурлыгындагы; *книга ин-октаво* — кәгазь битенең сигездән бере зурлыгындагы китап.

**ИНОМЫ'СЛИЕ** *ср. мн.* нет, *книж. устар.* — башкача уйлау, башкача фикерләү; *властный старик не терпел ни в ком иномыслия* — боерырга яратучан карт беркемнең дә башкача уйлавын яратмый иде.

**ИНОПЛЕМЕ'ННИК** *м.*, **ИНОПЛЕМЕ'ННИЦА** *ж. книж.* — башка кабилә кешесе, башка халык кешесе.

**ИНОРО'ДЕЦ** *м. офиц. дореевол.* — инородец (элекtә Россиядә рустан башка милләт кешесе).

**ИНОРО'ДНЫЙ** *книж.* — 1. (*чуждый*) ят, чит, башка; 2. бөтенләй башка үзенчәлекләргә ия булган; *инородные явления* — бөтенләй башка үзенчәлекләргә ия булган күренешләр.

**ИНОРО'ДЧЕСКИЙ** *офиц. дореевол.* — инородецлар...-ы; *инородческий вопрос* — инородецлар мәсьәләсе.

**ИНОСКАЗА'НИЕ** *ср. книж. лит.* — аллегория, читләтеп әйтелгән сүз, кинаяя; *он любит говорить иносказаниями* — ул кинаяләр белән сөйләргә ярата.

**ИНОСКАЗА'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — кинаялелек, аллегорик булу; *иносказательность выражения* — тәгъбирнең кинаялелеге.

**ИНОСКАЗА'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.* — аллегорик; читләтеп әйтелгән; кинаяле; *иносказательное выражение* — кинаяле сүз.

**ИНОСТРА'НЕЦ** *м.*, **ИНОСТРА'НКА** *ж.* — чит ил кешесе.

**ИНОСТРА'ННЫЙ** *книж.* — 1. чит ил...-ы; *иностранный корабль* — чит ил корабле; *иностранные товары* — чит ил товарлары; 2. чит; *иностранные языки* — чит телләр; 3. тышкы; *иностранная торговля* — тышкы сәүдә (чит илләр белән алып барыла торган сәүдә).

**ИНОСТРА'НЩИНА** *ж. мн.* нет, *разг. пренебр.* — иностранщина (капиталистик җәмгыятькә һәм аның идеологиясенә хас һәм прогрессив, социалистик идеологиягә дошман булган гадәтләр, йолалар, кыланышлар, сүзләр).

**ИНОХО'ДЕЦ** *м.* — юрга ат.

**И'НОХОДЬ** *ж. мн.* нет — юргалау.

**ИНОЯЗЫ'ЧНЫЙ** *книж.* — 1. чит телдә сөйләшә торган, башка телдә сөйләшә торган; *иноязычное население* — башка телдә сөйләшә торган халык; 2. чит тел ...-ы; *иноязычные слова* — чит тел сүзләре.

**ИНСИНУА'ТОР** *м. книж.* — инсинуатор, яла ягучы.

**ИНСИНУА'ЦИЯ** *ж. книж.* — инсинуация, яла ягу (берәр максат белән яла ягу; кемнең дә булса сүзләрен вөҗдансыз рәвештә бозып сөйләү).

**ИНСИНУИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. книж.* — яла ягу, ялган сөйләү.

**ИНСОЛЯ'ЦИЯ** *ж.* — инсоляция (1. *физ.* җир өстенең бер квадрат сантиметрына билгеле бер вакыт эчендә төшкән кояш яктысы һәм җылысы; 2. *мед.* кояш нурлары белән дәвалау; 3. *мед.* (*солнечный удар*) кояш сугу, эссе сугу).

**ИНСПЕКТИ'РОВАТЬ** *несов. офиц.* — тикшерү (эшнең дөреслеген, дөрес үтәлешен, барышын); инспекторлык итү.

**ИНСПЕКТИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд. книж.* — тикшерелү (инспектор тарафыннан).

**ИНСПЕ'КТОР** *м.* — инспектор (1. эшнең барышын, законның дөрес үтәлешен тикшерүче; *инспектор труда* — хезмәт инспекторы; 2. *воен.* хәрби идарәнең нинди дә булса бер эш тармагы башында торучы; *инспектор артиллерии* — артиллерия инспекторы; 3. *дореевол.* уку йортларында директор ярдәмчесе вазифасын үтәүче; *инспектор гимназии* — гимназия инспекторы).

**ИНСПЕКТОРА'Т** *м. мн.* нет, *книж.* — к. инспектура 1.

**ИНСПЕ'КТОРСКИЙ** — инспекторлык...-ы; инспектор...-ы; *инспекторские обязанности* — инспекторлык вазифалары; *инспекторская проверка* — инспектор тикшерүе.

**ИНСПЕ'КТОРСТВО** *ср. мн.* нет, *разг.* — инспекторлык; инспекторлык вазифасы.

**ИНСПЕ'КТОРСТВОВАТЬ** *несов. разг.* — инспектор булып эшләү, инспекторлык итү.

**ИНСПЕ'КТОРША** *ж. разг.* — инспектор хатыны.

**ИНСПЕКТРИ'СА** *ж. дореевол.* — инспектриса (революциягә кадәр кызлар өчен булган уку йортларының инспекторы).

**ИНСПЕКТУ'РА** *ж. книж.* — 1. инспектура (а. *только ед.* инспекторларның тик-

шерү системасы; 6. *офиц.* инспектор вазифасы); 2. *собир.* инспекторлар.

**ИНСПЕ'КЦИЯ** *ж. офиц.* — инспекция (1. инспекторлар тикшерүе; 2. к. инспектура а; 3. инспекторлык эшләрен алып бара торган орган—учреждение).

**ИНСПИРА'ТОР** *м. книж.* — коткычы, коткы таратучы, котыртучы.

**ИНСПИРА'ЦИЯ** *ж. книж.* — коткы, котырту, коткы салу.

**ИНСПИРИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.* — 1. коткы салу, котырту, яшерен коткы салу; 2. тарату; *инспирировать слухи о войне* — сугыш турында хәбәрләр тарату; 3. чуалту, вәсвәсәләү; *инспирировать общественное мнение* — җәмәгатьчелек фикерен вәсвәсәләү.

**ИНСПИРИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. страд. книж.* — 1. коткы салыну, котыртылу, яшерен коткы салыну; 2. таратылу.

**ИНСТА'НЦИЯ** *ж. офиц.* — инстанция (1. суд процессы стадиясе; 2. дәүләт идарәсе, профсоюз һ. б. органнар системаларында бер-берсенә үзара буйсынган баскычлар).

**ИНСТИ'НКТ** *м.* — инстинкт (1. *биол.* табигый сизү, табигый тойгы, эчке сизем; хайванның яшәү өчен әһәмиятле булган эшне, хәрәкәтне аңсыз рәвештә башкаруга сәләте; 2. *книж.* сизем, аңсыз рәвештә омтылу).

**ИНСТИКТИ'ВНО** *нареч.* — инстинктив рәвештә, инстинкт белән, ихтыярсыз, аңсыздан; *я инстинктивно оглянулся* — мин инстинктив рәвештә (ихтыярсыз) әйләнеп карадым.

**ИНСТИНКТИ'ВНЫЙ** *книж.* — 1. *биол.* инстинктив, инстинктка нигезләнгән; *инстинктивное чувство* — инстинктив тойгы; 2. инстинктив, ихтыярсыз эшләнгән, аңсыздан эшләнгән; *инстинктивное движение* — ихтыярсыз эшләнгән хәрәкәт, инстинктив хәрәкәт.

**ИНСТИТУ'Т** *м.* — институт (1. кайбер югары уку йортларының һәм гыйльми учреждениеләрнең исеме; 2. *юр.* иҗтимагый мөнәсәбәтне регулярлаштыра торган юридик нормалар җыелмасы; *институт брака* — никахланышу институты, ягъни никахланышуны регулярлаштыра торган юридик нормалар җыелмасы; 3. *дореВол.* югары катлау кызлары өчен ябык урта уку йорты).

**ИНСТИТУ'ТСКИЙ**—институт...-ы; *институтская профессура* — институт профессорлары.

**ИНСТРУКТА'Ж** *м. мн.* нет — инструктаж, инструкция бирү, күрсәтмәләр бирү.

**ИНСТРУКТИ'ВНЫЙ** *книж.* — инструктив (житәкче күрсәтмәләр бирә торган); *инструктивное письмо* — инструктив хат.

**ИНСТРУКТИ'РОВАНИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — к. инструктаж.

**ИНСТРУКТИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. книж.* — инструкция бирү, житәкче күрсәтмәләр бирү.

**ИНСТРУКТИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. страд. книж.* — инструкция бирелү, житәкче күрсәтмәләр бирелү.

**ИНСТРУ'КТОР** *м. мн.* нет — инструктор (нинди дә булса бер эш өлкәсендә инструкция бирүче).

**ИНСТРУ'КТОРСКИЙ** — инструкторлык ...-ы; инструкторлар...-ы; *инструкторские обязанности* — инструкторлык вазифалары; *инструкторские курсы* — инструкторлар курслары.

**ИНСТРУ'КТОРСТВО** *ср. мн.* нет — инструкторлык эше; инструкторлык вазифасы.

**ИНСТРУ'КЦИЯ** *ж.* — инструкция, кулланма, житәкче күрсәтмәләр.

**ИНСТРУМЕ'НТ** *м.* — 1. инструмент, корал; 2. *только ед. собир.* инструментлар (кораллар); *слесарь захватил с собой весь инструмент* — слесарь үзе белән бөтен инструментларын (коралларын) да алды.

**ИНСТРУМЕНТАЛИ'СТ** *м. муз.* — инструменталист (нинди дә булса музыка коралында уйный торган музыкант).

**ИНСТРУМЕНТА'ЛЬНЫЙ** — 1. *тех.* инструмент...-ы; инструментлар эшләүгә китә торган; *инструментальная сталь* — инструмент корычы; 2. инструментлар ясый торган; *инструментальная мастерская* — инструментлар ясый торган мастерской; 3. *муз.* инструменталь, инструментта уйнала торган; *инструментальная музыка* — инструменталь музыка.

**ИНСТРУМЕНТА'ЛЬЩИК** *м. спец.* — инструментальщик (инструментлар ясаучы).

**ИНСТРУМЕНТА'РИЙ** *м. книж. спец. собир.* — инструментлар.

**ИНСТРУМЕНТИ'РОВАТЬ, ИНСТРУМЕНТОВА'ТЬ** *сов.* и *несов. муз.* и *лит.* — музыка коралларына яраклаштыру, музыка коралларына иплэү (берәр музыкаль әсәрне).

**ИНСТРУМЕНТО'ВКА** *ж.* — инструментовка (1. *только ед. муз.* музыкаль әсәрне оркестр белән башкаруга яраштыру; 2. *муз.* музыка теориясенең аерым музыкаль инструментларның техникасын һәм художество сыйфатын, шулай ук музыкаль инструментларның оркестрда туплану принципларын өйрәнә торган бүлеге).

**ИНСУЛИ'Н** *м. мн.* нет, *мед.* — инсулин (хайван һәм балыкларның ашказаны асты бизләреннән алынган сыгынты; диабет (бирән) авыруы вакытында һәм бик нык ябыккан вакытта дару итеп кулланыла).

**ИНСУРГЕ'НТ** *м. книж. устар.* — инсургент, восстаниедә катнашучы, баш күтәрүче, фетнәче.

**ИНСУРГЕ'НТСКИЙ** *книж. устар.* — инсургент...-ы; инсургентлар...-ы; баш күтәрүче...-ы; баш күтәрүчеләр...-ы; восстаниедә катнашучылар...-ы; *инсургентская группа* — восстаниедә катнашучылар группасы.

**ИНСУРРЕКЦИО'ННЫЙ** *книж. устар.*— инсуррекция...-ы; кораллы восстание...-ы; *инсуррекционный план* — кораллы восстание планы.

**ИНСУРРЕ'КЦИЯ** *книж. устар.*—кораллы восстание (хөкүмәткә, властька каршы).

**ИНСЦЕНИ'РОВА'ТЬ** *сов.* и *несов.*—1. сәхнәләштерү (хикәяне, романны сәхнәгә куярга яраклаштыру); *инсценировать рассказ* — хикәяне сәхнәләштерү; 2. *перен.* ... булып кылану, салышу (берәр максат белән үзеңә янсә тирә-юньдә берәр хәл булган итеп күрсәтү); *инсценировать болезнь*— авыру булып кылану, авыруга салышу; *инсценировать нападение* — һөҗүм ясаган булып кылану.

**ИНСЦЕНИРО'ВКА** *ж. книж.* — 1. к. инсценировать; 2. инсценировка, сәхнәләштерелгән әсәр, пьеса.

**ИНТЕГРА'Л** *м. мат.* — интеграл (югары математикада: чиксез кечкенә саннар суммасы булган бөтен зурлык).

**ИНТЕГРА'ЛЬНЫЙ** — 1. *мат.* интеграль...; *интегральная функция* — интеграль функция; 2. *науч.* интеграль...; нык бәйләнешле; бөтеннән аерылмаслык кисәге булган; *интегральные элементы* — интеграль элементлар.

**ИНТЕГРА'ЦИЯ** *ж. книж.* — интеграция (1. к. интегрировать; 2. *науч.* нинди дә булса кисәкләрне яки элементларны бер бөтенгә берләштерү).

**ИНТЕГРИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. мат.*— интегралны табу (математик функциядә).

**ИНТЕЛЛЕ'КТ** *м. книж.* — интеллект, акыл, аң (кешенең уйлау, фикер йөртү сәләте).

**ИНТЕЛЛЕКТУАЛИ'ЗМ** *м.*— интеллектуализм (1. *псих.* психологиядә бөтен психик тормыш акыл эшчәнлегенә нигезләнгән дип расланый торган идеалистик юнәлеш; 2. *филос.* кешенең психик кичерешләрендә ихтыярның катнашы юк, бары тик интеллект кына роль уйный дигән идеалистик караш).

**ИНТЕЛЛЕКТУАЛИ'СТ** *м. филос. псих.*— интеллектуалист (интеллектуализм тарафдары).

**ИНТЕЛЛЕКТУА'ЛЬНЫЙ** *книж.* — интеллектуаль, акыл...-ы; рухи; *интеллектуальная способность человека* — кешенең акыл сәләте, кешенең интеллектуаль сәләте.

**ИНТЕЛЛИГЕ'НТ** *м.* — интеллигент (акыл хезмәте белән шөгыльләнүче укымышлы кеше).

**ИНТЕЛЛИГЕ'НТКА** *ж.*— к. интеллигент.

**ИНТЕЛЛИГЕ'НТНОСТЬ** *ж. мн.* нет — интеллигентлык, укымышлылык, белемлелек.

**ИНТЕЛЛИГЕ'НТНЫЙ** — 1. белемле, укымышлы, культуралы; *он оказался вполне интеллигентным человеком* — ул җитәрлек дәрәҗәдә укымышлы кеше булып чыкты; 2. интеллигентлар...-ы; *интеллигентный труд* — интеллигентлар хезмәте.

**ИНТЕЛЛИГЕ'НТСКИЙ** — интеллигентлык...-ы; интеллигентларча..., интеллигентларга хас; *интеллигентские привычки* — интеллигентлык гадәтләре, интеллигентларга хас гадәтләр.

**ИНТЕЛЛИГЕ'НЦИЯ** *ж. мн.* нет — интеллигенция (акыл хезмәте белән шөгыльләнүчеләр).

**ИНТЕЛЛИГИ'БЕЛЬНЫЙ** *филос.* — акыл белән генә танылa торган, материаль булмаган (идеалистик философиядә); *интеллигибельный мир*—материаль булмаган дөнья.

**ИНТЕНДА'НТ** *м.* — интендант (1. *воен.* интендантствода хезмәт итүче кеше; 2. *истор.* XVIII йөз ахырындагы буржуаз революциягә кадәр Франциядә — административ округ начальнигы; ул полиция, суд, финанс эшләре белән җитәкчелек иткән).

**ИНТЕНДА'НТСКИЙ** *дореволю.* — интендантство...-ы; интендант...-ы; *интендантский чиновник* — интендантство чиновнигы.

**ИНТЕНДА'НТСВО** *ср. воен.* — интендантство (армиядә хуҗалык эшләрен алып бара торган оешма).

**ИНТЕНСИ'ВНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— интенсивлык, киеренкелек.

**ИНТЕНСИ'ВНЫЙ** *книж.* — 1. интенсив, киеренке, күп көч куелган; *интенсивный труд* — интенсив хезмәт, киеренке хезмәт; 2. интенсив, күп җитештерүчән, файдалы; *интенсивная система сельского хозяйства* — авыл хуҗалыгының интенсив системасы (күп уңыш бирә торган системасы).

**ИНТЕНСИФИЦИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. книж.* — интенсивлаштыру, көчәйтү, куәтләндерү (көч куеп, берәр нәрсәнең үсешен, алга барышын тизләтү).

**ИНТЕНСИФИЦИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. страд. книж.* — интенсивлаштырылу, көчәйтелү, куәтләндерелү.

**ИНТЕРВА'Л** *м.*— 1. *книж.* (*промежуток*) интервал, ара; 2. *муз.* интервал (бер үк вакытта яки бер бер артлы чыккан ике тавышның калынлык-нечкәлегендәге аерма).

**ИНТЕРВЕНИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. книж.* — интервенция оештыру.

**ИНТЕРВЕ'НТ** *м. полит.* — интервент (интервенцияне оештыручы яки интервенциягә катнашучы).

**ИНТЕРВЕНЦИОНИ'СТ** *м. полит.* — интервенционист (интервенция яклы кеше).

**ИНТЕРВЕНЦИО'ННЫЙ** *полит.* — интервенция...-ы; *интервенционные войска* — интервенция гаскәрләре.

**ИНТЕРВЕ'НЦИЯ** *ж. полит.* — интервенция (революцияне бастыру, территорияне басып алу, үзенең хакимлеген урнаштыру, өстенлек яулап алу максатларын күздә тотып бер яки берничә дәүләтнең, коралы көч кулланып, икенче бер дәүләтнең эчке эшләренә катнашуы, тыгылуы).

**ИНТЕРВЬЮ'** *ср. нескл. книж.*— интервью (1. матбугат хәбәрчесенең нинди дә булса бер җәмәгать эшлеклесе белән матбугатта игълан итү өчен булган беседасы; 2. шул беседаның эчтәлеге язылган газета мәкаләсе).

**ИНТЕРВЬЮЕ'Р** *м. книж.* — интервьюер (интервью алучы журналист).

**ИНТЕРВЬЮИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.* — 1. интервью үткәрү; 2. *разг. шутл.* сорашу, белергә тырышып сорашу, төпченү, төпченеп сорашу.

**ИНТЕРВЬЮИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. страд.* — интервью үткәрелү.

**ИНТЕРЕ'С** *м.* — 1. интерес, кызыксыну,

теләк; *проявлять интерес к делу* — эшкә кызыксыну күрсәтү; *относиться к делу без всякого интереса* — эшкә һич тә кызыксынмыйча карау; 2. (*важность*) әһәмият; *это дело имеет общественный интерес* — бу эшнең иҗтимагый әһәмияте бар; 3. *разг.* (*выгода, смысл*) файда, мәгънә; *нет никакого интереса ехать туда* — анда барудан бер файда да (мәгънә дә) юк; 4. *только мн.* интерес, ихтыяҗ, сорау, кирәклек; *в интересах трудящихся* — хезмәт ияләренең ихтыяҗыннан чыгып, хезмәт ияләренең интересларын күз алдында тотып; 5. *только мн.* омтылышлар, теләкләр; *духовные интересы* — рухи омтылышлар; *животные интересы* — хайвани теләкләр. ◇ Играть на интерес *разг. устар.* — акчага уйнау (нинди дә булса уенны).

**ИНТЕРЕСА'НТ** *м. разг. устар.* — интересант, үз файдасын гына күздә тотучы, шәхси файдасы өчен генә эшләүче.

**ИНТЕРЕСА'НТКА** *ж. разг. устар.* — к. интересант.

**ИНТЕРЕ'СНИЧАТЬ** *несов. разг. фам.* — ягымлы булырга тырышу, сөйкемле булырга тырышу, кыланып (үзенә) каратырга тырышу.

**ИНТЕРЕ'СНО** *нареч.* — кызык, кызык итеп, кызыгырлык итеп, кызыктырырлык итеп; *интересно рассказывает* — кызык итеп сөйли, кызыгырлык итеп сөйли.

**ИНТЕРЕ'СНЫЙ** — 1. кызык, кызыклы, кызыктырырлык, кызыксынырлык *интересный рассказ* — кызыклы хикәя; 2. *разг.* сөйкемле, ягымлы, чибәр, гүзәл, матур; *интересная женщина* — сөйкемле (гүзәл, матур) хатын. ◇ В интересном положении *разг.* — йөкле, авырлы.

**ИНТЕРЕСОВА'ТЬ** *несов.* — кызыктыру, кызыксындыру; *его интересует техника* — аны техника кызыксындыра.

**ИНТЕРЕСОВА'ТЬСЯ** *несов.* — кызыксыну, кызыксыну күрсәтү; *интересоваться наукой* — фән белән кызыксыну.

**ИНТЕРМЕ'ДИЯ** *ж. театр. лит.* — интермедия (спектакльнең пәрдәләре арасында башкарыла торган кечкенә генә көлкеле пьеса).

**ИНТЕРНА'Т** *м. офиц.* — 1. интернат, торак; 2. *устар.* ябык уку йорты.

**ИНТЕРНА'ТСКИЙ** — интернат...-ы; *интернатское имущество* — интернат милке.

**ИНТЕРНАЦИОНА'Л** *м.* — интернационал (1. *истор.* халыкара берләшмә; *Коммунистический Интернационал* — Коммунистик Интернационал; 2. пролетариатның халыкара гимны; КПССның гимны).

**ИНТЕРНАЦИОНАЛИЗА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *полит.* — интернационализация (берәр территориядән, корылмадан, елгадан һ. б. билгеләнгән шартларда файдаланырга барлык дәүләтләргә договор буенча хокук бирү).

**ИНТЕРНАЦИОНАЛИЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. полит.* — интернационализацияләштерү, берәр нәрсәгә интернационализация игълан итү.

**ИНТЕРНАЦИОНАЛИЗИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. страд. полит.* — интернационализацияләштерелү, берәр нәрсәгә интернационализация игълан ителү.

**ИНТЕРНАЦИОНАЛИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *полит.* — интернационализм (1. буржуазияне бәреп төшерүдә һәм коммунизм төзү өчен көрәштә бөтен дөнья пролетариатының сыйнфый ярдәмлегe һәм теләктәшлеге; 2. барлык халыкларның азатлыгын һәм хокукта тигезлеген яклап чыгу һәм шовинизмга каршы көрәшү).

**ИНТЕРНАЦИОНАЛИ'СТ** *м.* — интернационалист (интернационализм тарафдары).

**ИНТЕРНАЦИОНАЛИСТИ'ЧЕСКИЙ** — интернационалистик; *интернационалистические взгляды* — интернационалистик карашлар.

**ИНТЕРНАЦИОНАЛИ'СТКА** *ж.* — к. интернационалист.

**ИНТЕРНАЦИОНАЛИ'СТСКИЙ** — интернационалистлар...-ы; интернационалистларча...; *интернационалистский подход к делу* — эшкә интернационалистларча мөнәсәбәттә булу.

**ИНТЕРНАЦИОНА'ЛЬНЫЙ** — 1. халыкара; *интернациональный гимн* — халыкара гимн; 2. интернационализм рухында..., интернационализм нигезендә...; *интернациональное воспитание молодёжи* — яшьләрне интернационализм рухында тәрбияләү.

**ИНТЕРНИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. офиц.* — интернировать итү (1. сугышучы дәүләтнең үзенә каршы сугышучы дәүләт гражданнарын кулга алып сугыш беткәнгә кадәр бер җиргә дә җибәрми тотуы; 2. сугышучы дәүләт гаскәре берәр нейтраль дәүләт территориясенә барып керсә, нейтраль дәүләтнең шул гаскәрләрне коралсызландыруы һәм вакытлыча үз дәүләтләренә чыгармый тотуы).

**ИНТЕРНИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. страд. офиц.* — интернировать ителү.

**ИНТЕРПЕЛ(Л)И'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. полит.* — интерпелляция ясау, хөкүмәткә сорау бирү.

**ИНТЕРПЕЛ(Л)Я'НТ** *м. полит.* — интерпелянт (парламентның интерпелляция ясаучы члены).

**ИНТЕРПЕЛ(Л)Я'ЦИЯ** *ж. полит.* — интерпелляция (парламентларда берничә депутатның имзасы белән нинди дә булса мөһим мәсьәлә буенча хөкүмәткә бирелгән язма сорау).

**ИНТЕРПОЛИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. науч.* — интерполировать итү, интерполяция ясау.

**ИНТЕРПОЛИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. страд. науч.* — интерполировать ителү, интерполяция ясалу.

**ИНТЕРПОЛЯ'ЦИЯ** *ж.* — интерполяция (1. *филол.* берәр авторның текстына башка бер кеше тарафыннан өстәлгән сүзләр яки җөмләләр; 2. *мат.* и *стат.* бирелгән берничә кыйммәте буенча нинди дә булса зурлыкның аралык кыйммәтен табу).

**ИНТЕРПРЕТА'ТОР** *м. книж.* — интерпретатор, интерпретацияләүче, аңлатучы, ачыклап бирүче; *интерпретатор зако-*

*нов* — законнарны аңлатучы (ачыклап бирүче), законнарны интерпретацияләүче.

**ИНТЕРПРЕТА'ЦИЯ** *ж. книж.* — интерпретация (1. берәр нәрсәне аңлату, мәгънәсен ачып бирү; 2. үзенең аңлатмасына нигезләп, нинди дә булса музыкаль, әдәби әсәрне яки драматик рольне иҗади башкару).

**ИНТЕРПРЕТИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. книж.* — интерпретация ясау, аңлату, ачыклау, мәгънәсен ачып бирү.

**ИНТЕРПРЕТИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. страд. книж.* — интерпретация ясалу, аңлатылу, ачыклану, аңлатып бирелү.

**ИНТЕРПУ'НКЦИЯ** *ж. мн.* нет, *грам.* — интерпункция (тыныш билгеләре куеп чыгу).

**ИНТЕРЬЕ'Р** *м. книж.* — интерьер (1. *устар.* бинаның эчке ягы; 2. *искус.* бинаның, бүлмәнең эчке күренеше төшерелгән картина; 3. хайванның эчке төзелеше).

**ИНТИ'МНИЧАТЬ** *несов. разг. фам.* — серләшү, эчке серләрне ачу.

**ИНТИ'МНОСТЬ** *ж.* — сердәшлек, үзара иң якын дуслык, ахирәтлек, чын күңелдән булган якынлык; *беседа их была проникнута интимностью* — аларның әңгәмәләре иң якын дуслык белән сугарылган иде.

**ИНТИ'МНЫЙ** — 1. чын күңелдән..., ихлас күңелдән...; *интимный разговор* — чын күңелдән сөйләшү; 2. иң якын, сердәш, ахирәт; *интимный друг* — иң якын дус, сердәш дус; 3. (*скрываемый от других*) яшерен, кешегә әйтелми торган; 4. женси; *интимная связь* — женси бәйләнеш.

**ИНТОКСИКА'ЦИЯ** *ж. мед.* — интоксикация, организмның агулануы; *алкогольная интоксикация* — алкоголь интоксикациясе, организмның алкоголь белән агулануы.

**ИНТОНАЦИО'ННЫЙ** *лингв.* — интонация...-ы; *интонационные особенности* — интонация үзенчәлекләре.

**ИНТОНА'ЦИЯ** *ж.* — интонация (1. *лингв.* сөйләмнең тавышны күтәрүгә һәм төшерүгә бәйләнгән ритмик-мелодик төзелеше; *вопросительная интонация* — сорау интонациясе; 2. *книж.* сөйләүченең үз сөйләменә булган мөнәсәбәтен белдерә торган тоны, сөйләү манерасы; 3. *муз.* җырлаганда яки музыка коралында уйнаганда тонның дөреслеге яки дөрес түгеллеге).

**ИНТОНИ'РОВАТЬ** *несов. книж.* — интонация ясау; *неправильно интонировать* — интонацияне ялгыш ясау.

**ИНТРИ'ГА** *ж.* — 1. интрига, астыртын хәйлә, мәкер; 2. *лит.* интрига (драмада яки романда төп вакыйгаларның үсеше, төп ситуация); 3. *устар.* гыйшык, мәхәббәт бәйләнеше.

**ИНТРИГА'Н** *м.*, **ИНТРИГА'НКА** *ж.* — интрига белән шөгыльләнүче, хәйлә коручы, мәкер коручы, интриган.

**ИНТРИГА'НСКИЙ** *разг.* — интриганнарча...; *интриганские поступки* — интриганнарча кыланышлар.

**ИНТРИГА'НСТВО** *ср.* — интриганлык.

**ИНТРИГОВА'ТЬ** *несов.* — 1. (*вести интригу*) интрига алып бару, хәйлә кору, кешегә баз казу; 2. (*заинтересовывать*) кызыктыру, кызыксындыру.

**ИНТРОДУ'КЦИЯ** *ж. муз.* — интродукция, кереш (музыкаль әсәрнең кереш өлеше.)

**ИНТРОСПЕКТИ'ВНЫЙ** *псих.* — интроспекция...-ы; интроспектив; *интроспективный метод* — интроспекция методы.

**ИНТРОСПЕ'КЦИЯ** *ж. псих.* — интроспекция (үз-үзеңне күзәтү; үз өстеңнән үзең күзәтүләр алып бару нигезендә психик тормышны өйрәнү).

**ИНТУИТИВИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *филос.* — интуитивизм (реакцион буржуаз философиядә чынбарлыкны дөрес танып-белү бары тик интуиция нигезендә генә була ала дип өйрәтә торган субъектив-идеалистик юнәлеш).

**ИНТУИТИВИ'СТ** *м. филос.* — интуитивист (интуитивизм тарафдары).

**ИНТУИТИ'ВНЫЙ** *книж.* — интуитив, интуициягә нигезләнгән; *интуитивное познание* — интуитив танып-белү.

**ИНТУИ'ЦИЯ** *ж. книж.* — интуиция (1. сизү, сизенү, сизгерлек, зирәклек; *по интуиции он разгадал намерения своего противника* — сизгерлеге аркасында ул үз дошманының ниятләрен белеп алды; 2. буржуаз реакцион философиядә: чынбарлыкны турыдан-туры, фәнни анализ катнашыннан башка танып-белү).

**ИНФАНТЕ'РИЯ** *ж. мн.* нет, *устар. воен.* — җәяүле гаскәр, пехота. ◇ **Генерал от инфантерии** *доревол.* — инфантерия генералы (җәяүле гаскәрләрдә иң югары генерал чины).

**ИНФАНТИЛИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *науч.* — инфантилизм, җитлекмәгән булу (организмның физик һәм психик яктан җитлекмәгән булуы, балалык яшендәге физик яки психик сыйфатларның олыгайгач та сакланган булуы).

**ИНФАНТИ'ЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — инфантильлек, җитлекмәгәнлек (организмның физик һәм психик яктан җитлекмәгәнлеге).

**ИНФАНТИ'ЛЬНЫЙ** *книж.* — инфантиль, инфантильлек...-ы; балалык яшенә хас; *инфантильный вид* — инфантиль кыяфәт, балалык яшенә хас кыяфәт.

**ИНФЕКЦИО'ННЫЙ** *мед.* — йогышлы; *инфекционные заболевания* — йогышлы авырулар.

**ИНФЕ'КЦИЯ** *ж. мед.* — инфекция, йогыш (йогышлы авырулар таратучы).

**ИНФИНИТИ'В** *м. лингв.* — инфинитив, исем фигыль.

**ИНФИЦИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. биол.* — йоктыру (йогышлы авыруны кешегә йоктыру).

**ИНФИЦИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. страд. биол.* — йоктырылу.

**ИНФЛУЭ'НЦА** и **ИНФЛЮЭ'НЦА** *ж. мн.* нет, *мед.* — грипп авыруы.

**ИНФЛЯ'ЦИЯ** *ж. экон.* — инфляция (чамадан тыш күбәю сәбәпле, кәгазь акчаның бәясе төшү).

**ИН-ФО'ЛИО** *тип.*—1. *нареч.* кәгазь битенең яртысы зурлыгында; *книга напечатана ин фолио* — китап кәгазь битенең яртысы зурлыгында басылган; 2. *в знач. нескл. прил.* — кәгазь битенең яртысы зурлыгындагы; *книга ин-фолио* — кәгазь битенең яртысы зурлыгындагы китап.

**ИНФОРМА'ТОР** *м. книж. офиц.* — информатор, информация ясаучы, хәбәр бирүче.

**ИНФОРМАЦИО'ННЫЙ** *книж. офиц.* — информация...-ы; информацияләр...-ы; информацион; *информационное бюро* — информация бюросы; *информационный отдел* — информацияләр бүлеге; *информационный бюллетень* — информацион бюллетень.

**ИНФОРМА'ЦИЯ** *ж. книж. офиц.* — 1. информация ясау; 2. информация, хәбәр, белдерү; *газетная информация* — газета информациясе, газетада басылган хәбәрләр.

**ИНФОРМИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. книж. офиц.* — информация ясау, хәбәр итү, белдерү.

**ИНФОРМИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов.* — 1. *книж. офиц. страд.* информация ясалу, белдерү ясалу, хәбәр ителү; 2. (*осведомиться*) информация алу.

**ИНФРАКРА'СНЫЙ: инфракрасные лучи** *физ.* — инфракызыл нурлар (күренми торган электромагнитик дулкыннар; аларның дулкын озынлыклары кызыл нурларныкына караганда зуррак була).

**ИНФУЗО'РИЯ** *ж. зоол.* — инфузория (бер күзәнәкле иң садә, суда яши торган микроскопик тереклек иясе).

**ИНЦИДЕ'НТ** *м. книж.* — инцидент, аңлашылмаучылык, күңелсез вакыйга, күңелсез бәрелеш.

**ИНЪЕ'КЦИЯ** *ж. мед.* — инъекция (тире астына дару җибәрү).

**ИО'Д** *м.* — иод (1. химик элемент; башлыча диңгез суүсемнәре көленнән табыла; Советлар Союзында нефть скважиналары суларыннан да табыла; 2. *мед.* шул элементтан ясалган дару.

**ИОДИ'ДЫ** *мн.* — иодидлар (иодның металлар белән кушылмалары).

**ИОДИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *мед.* — иодизм, иод белән агулану.

**ИО'ДИСТЫЙ** *хим.* — иодлы, иод катнашкан; *иодистый препарат* — иодлы препарат.

**ИО'ДНЫЙ** *хим.* — иод...-ы; *иодный раствор* — иод эремәсе.

**ИОДОФО'РМ** *м. мн.* нет, *хим. апт.* — иодоформ (медицинада дезинфекцияләү срелствосы).

**ИО'Н** *м. физ.* — ион (үзендә электр корылмасы булган атом яки атомнар группасы).

**ИОНИЗА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *физ.* — ионлашу (нинди дә булса әйбердә ионнарның барлыкка килүе).

**ИО'ННЫЙ** *физ.*— ион...-ы; *ионные токи*— ион токлары.

**ИОРКШИ'Р** *м. с.-х.* — иоркшир (тиз үсә торган эре дуңгыз токымы).

**ИОРКШИ'РСКИЙ** *с.-х.* — иоркшир...-ы; *иоркширская порода* — иоркшир токымы; *иоркширская свинья* — иоркшир дуңгызы.

**ИО'Т** *м. лингв.* — иот (латинча „j" хәрефе).

**ИО'ТА** *ж.* — иота (грек алфавитында „и" авазын белдерә торган „i" хәрефе). ◇ **Ни на йоту** *разг.* — бер дә, аз гына да, энә очы кадәр дә, тузан бөртеге кадәр дә.

**ИОТА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *лингв.* — иотация, иотлашу (иот авазының сузык аваз алдында килүе).

**ИПОТЕ'КА** *ж. спец.* — ипотека (капиталистик җәмгыятьтә күчми торган милекне закладка салу; шул заклад өчен алынган ссуда).

**ИПОХО'НДРИК** *м.* — ипохондрик, ипохондрия белән авыручы.

**ИПОХОНДРИ'ЧЕСКИЙ** *книж. мед.* — ипохондрия сәбәпле...; авырыйм дип шикләнеп...; *ипохондрическое помешательство* — ипохондрия сәбәпле акылдан шашу; авырыйм дип шикләнеп акылдан шашу.

**ИПОХО'НДРИЯ** *ж. мн.* нет, *книж.* — 1. *мед.* ипохондрия (булмаган авыруны барлыр дип шикләнеп авыруга сабышу); 2. күңел төшенкелеге, өметсезлек.

**ИППОДРО'М** *м.* — ипподром (ат чабыштыру мәйданы).

**ИПРИ'Т** *м. мн.* нет, *хим.* — иприт (агулы газ).

**ИР** *м. бот.* — кылыч үлән, сары сусын; *ир благовонный* — хуш исле сары сусын.

**ИРАНИ'СТ** *м. книж.* — иранист (иран телләре белгече).

**ИРА'НСКИЙ** — иран...-ы; Иран...-ы; *иранские языки* — иран телләре; *Иранское правительство* — Иран хөкүмәте.

**ИРА'НЦЫ** *мн.* — иранлылар, Иран халкы.

**ИРИ'ДИЙ** *м. мн.* нет, *хим.* — иридий (соргылт-ак төстәге бик авыр металл).

**И'РИС** *м.* — ирис (1. *бот.* эре чәчәкле күпьеллык үсемлек; 2. *анат.* күз карасы әйләнәсендәге яры).

**ИРИ'С** *м. мн.* нет — ирис (конфетның бер төре).

**ИРИ'СКА** *ж. разг.* — ириска (бер ирис конфеты).

**ИРЛА'НДЦЫ** *мн.* (*ед.* ирландец) — ирландиялеләр, Ирландия халкы.

**И'РНЫЙ** *бот.* — кылыч үлән...-ы, сары сусын...-ы; *ирный корень* — сары сусын тамыры (дару өчен кулланыла).

**И'РОД** *м. простореч. бран.* — залим, каты күңелле, шәфкатьсез, кансыз, газап чиктерүче.

**ИРОНИЗИ'РОВАТЬ** *несов. книж.* — ирония белән көлү, мыскыллап көлү, кимсетеп көлү.

**ИРОНИ'ЧЕСКИЙ** — ирониялe, астыртын көлеп әйтелгән; *ироническая улыбка* — ирониялe елмаю; *иронический ответ* — ирониялe җавап, астыртын көлеп әйтелгән җавап.

**ИРО'НИЯ** *ж. книж.* — ирония (1. *лит.* читләтеп әйтү, нечкәләп оста итеп көлү; мыскыллауны аңлата торган мактау сүзләре; 2. астыртын гына мыскыллап көлү)

**ИРРАДИА'ЦИЯ** *ж.* — иррадиация (1. *опт.* яктыртылган әйбернең яктыртылмаган чактагыга караганда зуррак кебек булып күренүеннән гыйбарәт булган оптик күренеш; мәсәлән, электр лампочкасы чыбыгының кызган чакта кызмагандагыга караганда юанрак булып күренүе; 2. *мед.* нинди дә булса авырткан урын тирәсендә сызлау сизү).

**ИРРАЦИОНАЛИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *филос.* — иррационализм (1. идеалистик философиядә чиктән тыш реакцион юнәлеш; бу юнәлеш акыл белән ирешеп булмаган һәм закончалыкка ят булган иррациональ башлангычны, очраклы, сукыр ихтыярны һ. б. ш. чынбарлыкның нигезе дип раслый һәм фәнни логик танып-белүне инкарь итә).

**ИРРАЦИОНА'ЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — иррациональлек.

**ИРРАЦИОНА'ЛЬНЫЙ** — иррациональ (1. *филос.* идеалистик философиядә — логик төшенчә белән әйтеп бирү мөмкин булмаган, акыл ирешә алмый торган, мистик; 2. *мат.* берәмлек белән үлчәнелми торган).

**ИРРЕА'ЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — реаль түгеллек.

**ИРРЕА'ЛЬНЫЙ** *книж.* — ирреаль; реаль булмаган, чынбарлыкта булмаган, чынбарлыкта яшәми торган; *ирреальные явления* — ирреаль күренешләр, реаль булмаган күренешләр.

**ИРРЕГУЛЯ'РНЫЙ** — 1. *книж. устар.* берничнди тәртипкә буйсынмый торган; *иррегулярное явление* — берниди тәртипкә буйсынмый торган күренеш; 2. *воен.* иррегуляр...; регуляр булмаган; регуляр армия составына керми торган; *иррегулярные войска* — иррегуляр (регуляр булмаган) гаскәрләр.

**ИРРИГА'ТОР** *м. мед.* — ирригатор (1. организмдагы яраларны, куышлыкларны юу приборы; 2. ирригация эшләре белгече, сугару эшләре белгече).

**ИРРИГАЦИО'ННЫЙ** *спец.* — сугару...-ы; *ирригационная система* — сугару системасы.

**ИРРИГА'ЦИЯ** *ж. спец.* — ирригация (1. *с.-х.* арыклар-каналлар системасы буенча су җибәреп коры җирләрне сугару; 2. *мед.* сыеклык сиптереп, яраны, тәндәге куышлыкларны юу).

**ИСК** *м. офиц.* — дәгъва (берәр кешедән акча яки милек түләтүне сорап судка мөрәҗәгать итү).

**ИСКАЖА'ТЬ** *несов. книж.* — бозу, бозып күрсәтү.

**ИСКАЖА'ТЬСЯ** *несов. книж.* — бозылу, бозып күрсәтелү.

**ИСКАЖЕ'НИЕ** *ср. книж.* — 1. к. искажать; *искажение плана* — планны бозу (бозып күрсәтү); 2. ялгыш, хата; *в книге обнаружено много искажений* — китапта бик күп хаталар табылды.

**ИСКАЖЁННЫЙ** *книж.* — 1. бозылган; *искажённые слова* — бозылган сүзләр; 2. сытылган, сытык; *искажённое от злобы лицо* — ачудан сытылган чырай (йөз).

**ИСКАЗИ'ТЬ** *сов.* — к. искажать.

**ИСКАЗИ'ТЬСЯ** *сов.* — к. искажаться.

**ИСКАЛЕ'ЧИВАТЬ** *несов.* — к. искалечить.

**ИСКАЛЕ'ЧИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. искалечиться; 2. *страд.* имгәтелү, гарипләнделү.

**ИСКАЛЕ'ЧИТЬ** *сов.* — 1. имгәтү, гарипләндерү; 2. вату, ватып бетерү, эштән чыгару; *искалечить игрушку* — уенчыкны ватып бетерү.

**ИСКАЛЕ'ЧИТЬСЯ** *сов. разг.* — гарипләнү, имгәнү.

**ИСКА'ЛЫВАТЬ** *несов.* — к. исколоть.

**ИСКА'ЛЫВАТЬСЯ** *несов.* — к. исколоться.

**ИСКА'НИЕ** *ср. книж.* — эзләү, эзләнү.

**ИСКА'ПАТЬ** *сов. разг.* — 1. чәчрәтеп буяп бетерү, тамызып буяп бетерү; *искапать чернилами* — кара тамызып буяп бетерү; 2. *простореч.* тамызып (тотып) бетерү, чәчрәтеп (тотып) бетерү; *искапал всё лекарство* — бөтен даруны тамызып бетердем.

**ИСКА'ПЫВАТЬ** I *несов.* — к. искапать.

**ИСКА'ПЫВАТЬ** II *несов.* — к. ископать.

**ИСКА'РМЛИВАТЬ** *несов. разг.* — к. искормить.

**ИСКА'РМЛИВАТЬСЯ** *несов. страд. разг.* — ашатып бетерелү (азык).

**ИСКА'ТЕЛЬ** *м. книж.* — 1. эзләүче, эзләнүче, эзләп йөрүче; 2. *спец.* эзләгеч (оптик приборларда, мәсәлән, фотоаппаратта, күзәтелә торган әйберне табуны җиңеләйтә торган җайланма).

**ИСКА'ТЕЛЬНИЦА** *ж. книж.* — к. искатель 1.

**ИСКА'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж. устар.* — ялагайланучанлык, ярарга тырышучанлык.

**ИСКА'ТЕЛЬНЫЙ** *книж. устар.* — ярарга тырышучан; ялагайланулы; ялагай; *искательный взгляд* — ялагайланулы караш.

**ИСКА'ТЕЛЬСТВО** *ср. мн.* нет, *книж. устар.* — ялагайлык, ялагайланучанлык, ярарга тырышучанлык, тәлинкә тоту.

**ИСКА'ТЬ** *несов.* — 1. эзләү; *искать потерянную вещь* — югалган әйберне эзләү; 2. *офиц.* дәгъва итү, таләп итү; *учреждение искало с ответчика тысячу рублей* — учреждение җавапка тартылган кешедән мең сум таләп итте; 3. *книж. устар.* ...-га тырышу; *враги искали его погубить* — дошманнар аны һәлак итәргә тырыштылар; 4. *разг. устар.* (*заискивать*) ярарга тырышу, ялагайлану, тәлинкә тоту. ◇ **Искать глазами** — күрергә тырышу.

**ИСКА'ШИВАТЬ** *несов. разг.* — к. искосить.

**ИСКА'ШИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. к. искоситься; 2. *страд.* кәкрәйтелү, кыегайтылу.

**И'СКИВАТЬ** *разг. многокр.* — эзләштергәләү.

**ИСКЛЕВА'ТЬ** *сов.* — 1. чукып яралап бетерү; 2. *обл.* чукып ашап бетерү.

**ИСКЛЁВЫВАТЬ** *несов. разг.* — к. исклевать.

**ИСКЛЁВЫВАТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. чукылып яраланып бетү; 2. чукылып бетү.

**ИСКЛЮЧА'ТЬ** *несов.* — к. исключить.

**ИСКЛЮЧА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — чыгарылу, чыгарып ташлану, төшерелү, төшереп калдырылу.

**ИСКЛЮЧА'Я** *книж.* — 1. башка; *пришли все, исключая Иванова* — Ивановтан башка бөтенесе дә килде; 2. чыгарып, төшереп калдырып, төшереп калдыруы белән; *исключая эти статьи из сметы, составитель заботился о сохранении средств* — сметаны төзүче, бу статьяларны төшереп калдыруы белән, средстволарны саклау турында кайгырткан.

**ИСКЛЮЧЕ'НИЕ** *ср. книж.* — 1. төшерү, чыгару, чыгарып ташлау, сызып ташлау; *исключение из списков* — исемлектән төшерү, исемлектән сызып ташлау; 2. чыгарма; *ни для кого не может быть исключений* — беркем өчен дә чыгарма булуы мөмкин түгел. ◇ **За исключением** — исәпкә алмаганда, санамаганда.

**ИСКЛЮЧИ'ТЕЛЬНО** — 1. *нареч.* искиткеч, аеруча, бигрәк тә; *исключительно вкусное блюдо* — искиткеч тәмле аш; 2. фәкать, бары, тик, бары тик, ялгыз гына; 3. *канц.* ...-га кадәр генә; ...-не кертмичә; *прочесть до пятой главы исключительно* — бишенче бүлеккә кадәр генә укырга (ягъни дүрт бүлекне тулысынча укырга).

**ИСКЛЮЧИ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. гадәттән тыш булу; *исключительность такого явления* — андый күренешнең гадәттән тыш булуы; 2. өстенлек, югарылык, бик яхшы булу; *исключительность этого товара* — бу товарның бик яхшы булуы; 3. аеруча өстенлек бирү; *всякая проповедь расовой или национальной исключительности, или ненависти и пренебрежения — карается законом* — бер расага яки милләткә карата аеруча өстенлек бирүгә, яки дошманлык күрсәтүгә һәм кимсетүгә һәртөрле өндәүләр закон тарафыннан җәзалана.

**ИСКЛЮЧИ'ТЕЛЬНЫЙ** — 1. *книж. офиц.* аерым; *исключительные законы* — аерым законнар; 2. гадәттән тыш; *исключительный случай* — гадәттән тыш вакыйга; 3. бик яхшы, иң яхшы, искиткеч, бик шәп; *товар исключительного качества* — бик яхшы сыйфатлы товар.

**ИСКЛЮЧИ'ТЬ** *сов.* — 1. чыгару, чыгарып ташлау, төшерү; *исключить из списков* — исемлекләрдән чыгару; 2. юл калдырмау; *исключить возможность невыполнения плана* — план үтәлмәү ихтималына юл калдырмау.

**ИСКОВЕ'РКАТЬ** *сов. разг.* — 1. (*испортить, изуродовать*) ватып бетерү, бозып бетерү; *сильный ветер исковеркал лёгкие постройки* — көчле жил җиңел корылмаларны ватып бетерде; 2. (*неправильно изложить*) бозып бирү, бозып сөйләү, бозып күрсәтү, бозып язу; *исковеркать чужую мысль* — кеше фикерен бозып бирү (бозып сөйләү).

**ИСКОВЕ'РКАТЬСЯ** *сов. простореч.* — бозылу, бозылып бетү.

**ИСКОВО'Й** *офиц.* — дәгъва...-ы; *исковое заявление* — дәгъва гаризасы.

**ИСКОВЫ'РИВАТЬ** *несов. разг.* — к. исковырять.

**ИСКОВЫ'РИВАТЬСЯ** *несов. страд. разг.* — чокып бетерелү, чокып бозып бетерелү.

**ИСКОВЫРЯ'ТЬ** *сов. разг.* — чокып бетерү, чокып бозып бетерү.

**ИСКОЛА'ЧИВАТЬ** *несов. разг.* — к. исколотить.

**ИСКОЛА'ЧИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. к. исколотиться; 2 *страд.* кага-кага ватып бетерелү, кага-кага бозып бетерелү; кагып чуарлап бетерелү.

**ИСКОЛЕСИ'ТЬ** *сов. разг.* — 1. (*изъездить*) йөреп чыгу, йөреп бетерү; 2. ергалап бетерү (тәгәрмәч эзе белән).

**ИСКОЛОТИ'ТЬ** *сов. разг.* — 1. кыйнап ташлау; тукмап ташлау; *его сильно исколотили* — аны бик нык кыйнап ташлаганнар; 2. кага-кага ватып бетерү, кага-кага бозып бетерү; *исколотить молоток* — кагакага чүкечне ватып бетерү; 3. кагып, тишкәләп чуарлап бетерү; *исколотить стену гвоздями* — стенаны кадак кагып, тишкәләп чуарлап бетерү; 4. *простореч.* кагып бетерү, (кагуга) тотып бетерү; *исколотить все гвозди* — барлык кадакны кагып бетерү.

**ИСКОЛОТИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — кага-кага ватылып бетү, кага-кага бозылып бетү.

**ИСКОЛО'ТЬ** *сов.* — чәнечкәләп бетерү, чәнчеп тишкәләп бетерү, чәнчеп яралап бетерү.

**ИСКОЛО'ТЬСЯ** *сов.* — чәнчелеп тишкәләнеп бетү, чәнчелеп яраланып бетү.

**ИСКОЛУПА'ТЬ** *сов. простореч.* — к. исковырять.

**ИСКОЛУ'ПЫВАТЬ** *несов. простореч.* — к. исколупать.

**ИСКО'МКАТЬ** *сов. разг.* — йомарлап бетерү, бөгәрләп бетерү.

**ИСКО'МКАТЬСЯ** *сов. разг.* — йомарланып бетү, бөгәрләнеп бетү.

**ИСКО'МЫЙ** *книж.* — 1. *мат.* эзләнелә торган, табылырга тиеш булган (зурлык); 2. эзләнелә торган, ачыкланырга тиеш булган; *рассуждая так, мы придём к искомому выводу* — шулай фикер йөртә торгач, без эзләнелә торган нәтиҗәгә килербез.

**ИСКОНИ'** *нареч. устар.* — борын-борыннан, борын заманнан бирле, элек-электән, борынгыдан, әллә кайчаннан бирле, бик күптәннән.

**ИСКО'ННЫЙ** — күптәнге, төп; *исконный владелец* — күптәнге хуҗа, төп хуҗа.

**ИСКОНОПА'ТИТЬ** *сов.* — 1. *спец.* (*конопатя, израсходовать*) мүкләүгә тотып бетерү (мәсәлән, сүсне); 2. *простореч.* (*обезобразить*) ямьсезләп бетерү, шыксызлап бетерү (чәчәк авыруы, йөзне).

**ИСКОНОПА'ЧИВАТЬ** *несов.* — к. исконопатить.

**ИСКОНОПА'ЧИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. *спец.* (*израсходоваться*) мүкләүгә тотылып бетү (мәсәлән, сүс); 2. *простореч.* (*обезобра-*

*зиться)* ямьсезләнеп бетү, шыксызланып бетү (чәчәк авыруыннан).

**ИСКОПА'ЕМЫЙ** *книж.* — 1. *мин. (о рудах и минералах)* казып табыла торган, казылма...; 2. *только мн. в знач. сущ.* казылмалар, казылма әйберләр; *полезные ископаемые* — файдалы казылмалар; 3. *геол.* и *палеонт.* казылмаларда табыла торган; *ископаемые растения* — казылмаларда табыла торган үсемлек калдыклары; 4. *перен. ирон.* иске фикерле кеше.

**ИСКОПА'ТЬ** *сов.* — казып чокырландырып бетерү, казып бетерү.

**ИСКОПТИ'ТЬ** *сов. разг.* — корымландырып бетерү, корым белән пычратып бетерү, сөремләндереп бетерү.

**ИСКОПТИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — корымланып бетү, сөремләнеп бетү.

**ИСКОРЁЖИВАТЬ** *несов. простореч.* — к. искорёжить.

**ИСКОРЁЖИВАТЬСЯ** *несов. простореч.* — 1. к. искорёжиться; 2. *страд.* калҗайтып бетерелү.

**ИСКОРЁЖИТЬ** *сов. простореч.* — калҗайтып бетерү; *искорёжить картон* — катырганы калҗайтып бетерү.

**ИСКОРЁЖИТЬСЯ** *сов. простореч.* — калҗаеп бетү; *переплёты у книг от сухости искорёжились* — китапларның тышлары корылыктан калҗаеп беткән.

**ИСКОРЕНЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — тамырын корыту, юк итү, бетерү; *искоренение зла* — явызлыкның тамырын корыту; *искоренение недостатков* — җитешсезлекләрне бетерү.

**ИСКОРЕНИ'ТЬ** *сов. книж.* — тамырын корыту, юк итү, юкка чыгару, бетерү.

**ИСКОРЕНИ'ТЬСЯ** *сов. книж.* — тамыры корү, юкка чыгу, бетү.

**ИСКОРЕНЯ'ТЬ** *несов. книж.* — к. искоренить.

**ИСКОРЕНЯ'ТЬСЯ** *несов. книж.* — 1. к. искорениться; 2. *страд.* тамыры корытылу, юк ителү, юкка чыгарылу.

**И'СКОРКА** *ж.* — к. искра.

**ИСКОРМИ'ТЬ** *сов. разг.* — ашатып бетерү, ашатуга тотып бетерү.

**ИСКОРО'БИТЬ** *сов. разг.* — к. искорёжить.

**ИСКОРО'БИТЬСЯ** *сов. разг.* — к. искорёжиться.

**И'СКОСА** *нареч. разг.* — кырын гына, астан гына, кырын күз белән.

**ИСКОСИ'ТЬ** *сов. разг.* — 1. *(сделать кривым, косым)* кәкрәйтү, чалышайту; 2. *(о косе)* үтмәсләндерү, кыршылдыру (күп чабып).

**ИСКОСИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. *(сделаться кривым, косым)* кәкрәю, чалышаю; 2. *(о косе)* үтмәсләнү, кыршылу.

**ИСКОСОБО'ЧИТЬСЯ** *сов. простореч.* — янтаеп бетү, кыйшаеп бетү.

**ИСКО'СОК** *м. обл.* — үтмәс чалгы, үтмәсләнгән чалгы.

**И'СКРА** *ж.* — 1. очкын; *выбить искру из камня* — ташка бәреп очкын чыгару; *электрическая искра* — электр очкыны; 2. чаткы; *алмазные искры* — алмаз чаткылары; 3. энҗедәй бөртек; *искры снега* — энҗедәй кар бөртекләре; 4. *перен.* чаткы; *искры надежды* — өмет чаткылары; *искра таланта* — талант чаткысы. ◇ **Искры посыпались из глаз** *разг.* — күзеннән утлар чәчрәде, күзеннән утлар күренде. **Из искры возгорится пламя** — очкыннан ялкын кабынып.

**ИСКРА'ИВАТЬ** *несов. порт.* — к. искроить.

**ИСКРА'ИВАТЬСЯ** *несов. порт.* — к. искроиться.

**ИСКРА'СИТЬ** *сов. разг.* — *(израсходовать)* буяп бетерү, буяуны тотып бетерү.

**ИСКРА'СИТЬСЯ** *сов. разг.* — буяуга тотылып бетү.

**ИСКРА'ШИВАТЬ** *несов. разг.* — к. искрасить.

**ИСКРА'ШИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. к. искраситься; 2. *страд.* буяуга тотып бетерелү.

**ИСКРЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *тех.* — очкын чыгару, чаткы чыгару.

**И'СКРЕННЕ, И'СКРЕННО** *нареч.* — чын күңелдән, ихлас күңелдән, чын йөрәктән, ихлас йөрәктән; *искренно преданный* — чын күңелдән бирелгән; *говорю вам это вполне искренно* — моны мин сезгә ихлас күңелдән әйтәм.

**И'СКРЕННИЙ** *разг.* — эчкерсез, саф, саф күңелле, турылыклы, ихлас күңелле, керсез күңелле, дөрестлекне сөюче; *искренний человек* — турылыклы кеше; ихлас күңелле кеше; *искренние чувства* — саф тойгылар.

**И'СКРЕННИЧАТЬ** *несов. разг. фам.* — 1. *(говорить, притворяясь искренним)* турылыклы булып кылану, саф күңелдән сөйләгән булып кылану; 2. *шутл. (вести дружески-откровенный разговор)* серләшү, ихлас күңелдән сөйләшү.

**И'СКРЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет — эчкерсезлек, саф күңеллелек, ихлас күңеллелек, керсез күңеллелек.

**И'СКРЕННЫЙ** — к. искренний.

**ИСКРЕСТИ'ТЬ** *сов. простореч.* — аркылы-торкылы сызып бетерү.

**ИСКРИВИ'ТЬ** *сов.* — 1. кәкрәйтү; *искривить гвоздь* — кадакны кәкрәйтү; 2. сыту, бозу, чыту, чалышайту; *искривить лицо* — чырай сыту, йөз чыту. ◇ **Искривить линию** *газет.* — дөрес линияне бозу, дөрес политикадан читкә тайпылу.

**ИСКРИВИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. кәкрәю; *гвоздь искривился* — кадак кәкрәйде; 2. *перен. (о лице)* сытылу, бозылу, чытылу, чалышаю, кыйшаю.

**ИСКРИВЛЕ'НИЕ** *ср.* — 1. к. искривить, искривиться; 2. бөгелгән урын, кәкрәйгән урын; *на трубах много искривлений* — трубаларның бөгелгән урыннары бик күп; 3. *перен. газет. полит.* бозу, тайпылыш; *искривление классовой линии* — сыйнфый линияне бозу, сыйнфый линиядән тайпылыш.

**ИСКРИВЛЯ'ТЬ** — к. искривить.

**ИСКРИВЛЯ'ТЬСЯ** I *несов.* — 1. к. искривиться; 2. *страд.* кәкрәйтелү.

**ИСКРИВЛЯ'ТЬСЯ** II *сов.* — кыланчыкка әверелү, кыланчыкланып бетү.

**И'СКРИСТЫЙ** и **ИСКРИ'СТЫЙ** — чемердәп тора торган; уйнап тора торган; *искристое вино* — чемердәп тора торган аракы.

**ИСКРИ'ТЬ** *несов. тех.* — очкын чыгару, чаткы чыгару (житәрлек тыгыз контакт булмаганда электр приборының очкын чыгаруы).

**ИСКРИ'ТЬСЯ** *несов. книж.* — 1. жемелдәү, жемелдәп тору, ялтырау, ялтырап тору; 2. *перен.* балку; *ум искрился в его взгляде* — аның карашында акыллылык балкый иде.

**ИСКРОВА'ВИТЬ** *сов. разг.* — к. искровянить.

**И'СКРОВЕЦ** *м. истор.* — искрачы (1900 нче елда В. И. Ленин тарафыннан оештырылган „Искра" газетасы группасына кергән революционер).

**ИСКРОВО'Й** *спец.*—очкын...-ы; чаткы...-ы; *искровой свет* — очкын яктысы. ◇ Искровой телеграф *устар.* — радиотелеграф.

**ИСКРОВЯНИ'ТЬ** *сов. разг.* — канга батыру, канга буяп бетерү (җәрәхәтләп).

**ИСКРОВЯНИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — канга буялып бетү, канга буялу (җәрәхәтләнеп).

**ИСКРОГАСИ'ТЕЛЬ** *м. тех.* — к. искроудержатель.

**ИСКРОИ'ТЬ** *сов. порт.* — кием кисү; кием кисүгә тотып бетерү (материяне).

**ИСКРОМЁТНЫЙ** *поэт.* — 1. очкын чәчә торган; 2. *перен.* үткен, көйдергеч, көйдереп ала торган, яндырып ала торган; *искромётный взгляд* — көйдереп ала торган караш.

**ИСКРОМСА'ТЬ** *сов. разг.* — ботарлап бетерү, кискәләп бетерү, тураклап бетерү.

**ИСКРОМСА'ТЬСЯ** *сов. простореч.* — ботарланып бетү, кискәләнеп бетү, тураклanып бетү, туралып бетү.

**ИСКРОПИ'ТЬ** *сов. простореч.* — бөркеп пычратып бетерү, бөркеп чылатып бетерү, сибәләп чылатып бетерү.

**ИСКРОУДЕРЖА'ТЕЛЬ** *м. тех.* — очкын тоткыч (мәсәлән, паровоз, фабрика моржаларына каплаган челтәрле тимер).

**ИСКРОУЛОВИ'ТЕЛЬ** *м. тех.* — к. искроудержатель.

**ИСКРОШИ'ТЬ** *сов.* — 1. (*измельчить*) ваклап бетерү, валчыкландырып бетерү, турап бетерү, тураклап бетерү, кискәләп бетерү; 2. *перен. разг.* турау, тураклау (кылыч белән); *кавалеристы искрошили врага* — кавалеристлар дошманны турадылар.

**ИСКРОШИ'ТЬСЯ** *сов.* — ваклanып бетү, валчыкланып бетү, кисәкләнеп бетү, тураклanып бетү.

**ИСКРУТИ'ТЬ** *сов. простореч.* — 1. бөтереп чуалтып бетерү; бөтереп бозып бетерү; *якорную верёвку совсем искрутили* — якорь бавын бөтереп, чуалтып бетергәннәр; 2. *обл.* ишүгә тотып бетерү; *на верёвки искрутили всю пеньку* — барлык сүсне бау ишүгә тотып бетергәннәр.

**ИСКРУТИ'ТЬСЯ** *сов. простореч.* — бөтерелеп бозылып бетү, бөтерелеп чуалып бетү.

**ИСКРУ'ЧИВАТЬ** *несов. простореч.* — к. искрутить.

**ИСКРУ'ЧИВАТЬСЯ** *несов. простореч.* — к. искрутиться.

**ИСКРЯ'К** *м. разг. истор.* — к. искровец.

**ИСКУПА'ТЬ** I *сов.* — к. выкупать.

**ИСКУПА'ТЬ** II *несов.* — к. искупить.

**ИСКУПА'ТЬСЯ** I *сов.* — к. выкупаться.

**ИСКУПА'ТЬСЯ** II *несов.* — к. искупиться.

**ИСКУПИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.* — йолу...-ы, коткаргыч, аклагыч; *искупительная жертва* — йолу корбаны.

**ИСКУПИ'ТЬ** *сов. книж.* — 1. йолу; *искупить свою вину* — үзеңнең гаебеңне йолу; 2. каплау; *искупить прилежанием недостаток способностей* — сәләт җитенкерәмәвен тырышлык белән каплау.

**ИСКУПИ'ТЬСЯ** *сов. книж.* — йолыну, гафу ителү, кичерелү; *все преступления его давно искупились* — аның барлык җинаятьләре күптән йолындылар (кичерелделәр).

**ИСКУ'РИВАТЬ** *несов. разг.* — к. искурить.

**ИСКУ'РИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — к. искуриться.

**ИСКУРИ'ТЬ** *сов. разг.* — тартып бетерү, тартуга тотып бетерү; *за день искурил пачку папирос* — бер көнгә бер пачка папирос тартып бетердем.

**ИСКУРИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — тартылып бетү; *папироса искурилась* — папирос тартылып бетте.

**ИСКУ'С** *м. книж.* — сынау; *тяжёлый искус* — авыр сынау; *выдержать искус* — сынаудан узу.

**ИСКУСА'ТЬ** *сов.* — тешләп бетерү, чәйнәп бетерү; талау; *прохожего искусали собаки* — узып баручыны этләр талаган.

**ИСКУСИ'ТЕЛЬ** *м.*, **ИСКУСИ'ТЕЛЬНИЦА** *ж. книж.* — күңел аздыручы, вәсвәсәләүче.

**ИСКУСИ'ТЬ** *сов. книж. устар.* — 1. (*соблазнить*) күңелен аздыру, кызыктыру, вәсвәсәләү; 2. (*испытать*) сынау, сынап карау.

**ИСКУСИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. *книж.* күнегү, остару, шомару, яхшы үзләштерү; *он искусился в технике* — ул техниканы яхшы үзләштергән; 2. *разг.* (*соблазниться*) вәсвәсәләнү, коткыга бирелү.

**ИСКУ'СНИК** *м.*, **ИСКУ'СНИЦА** *ж. разг.* — оста; *большой искусник в своём деле* — үз эшенең остасы.

**ИСКУ'СНО** *нареч.* — оста итеп.

**ИСКУ'СНЫЙ** — 1. оста; *искусный портной* — оста тегүче; 2. оста эшләнгән, белеп эшләнгән; *искусная работа* — оста эшләнгән эш.

**ИСКУ'ССТВЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — ясалмалык.

**ИСКУ'ССТВЕННЫЙ** — ясалма; *искусственная улыбка* — ясалма елмаю. ◇ Искусственные зубы — куелган тешләр.

**ИСКУ'ССТВО** *ср.* — 1. сәнгать; *изобразительные искусства* — сынлы сәнгатьләр;

*произведения искусства* — сәнгать әсәрләре; 2. осталык; *искусство вышивания* — чигү осталыгы; *военное искусство* — хәрби осталык; *он с большим искусством вёл свои дела* — ул үзенең эшләрен зур осталык белән башкара иде (алып бара иде). ◇ **Из любви к искусству** *разг. шутл.* — бары эшне яратудан чыгып кына; эшне яратканга күрә генә (үзенә файда китерү теләге белән түгел).

**ИСКУССТВОВЕ'Д** *м.* — сәнгать белеме галиме.

**ИСКУССТВОВЕ'ДЕНИЕ** *ср. мн.* нет — сәнгать белеме, сәнгать фәне, сәнгать турындагы фән.

**ИСКУССТВОВЕ'ДНЫЙ** и **ИСКУССТВОВЕ'ДЧЕСКИЙ** — сәнгать фәне...-ы; сәнгать фәннәре...-ы; *искусствоведческое отделение* — сәнгать фәннәре бүлеге.

**ИСКУССТВОЗНА'НИЕ** *ср. мн.* нет — к. искусствоведение.

**ИСКУ'СЫВАТЬ** *несов.* — к. искусать.

**ИСКУ'СЫВАТЬСЯ** *несов.* — тешләнеп бетү.

**ИСКУША'ТЬ** *несов.* — к. искусить.

**ИСКУША'ТЬСЯ** *несов.* — 1. азу, вәсвәсәләнү; 2. *страд.* аздырылу, вәсвәсәләндерелү.

**ИСКУШЕ'НИЕ** *ср. книж.* — 1. азу, вәсвәсәгә бирелү; аздыру, вәсвәсәләү; 2. (*соблазн*) көчле аздыргыч, вәсвәсә, котккы.

**ИСКУШЁННЫЙ** *книж.* — 1. *устар.* (*соблазнённый*) аздырылган, вәсвәсәгә бирелгән; 2. остарган, шомарган; *искушённый опытом* — тәҗрибә белән остарган; 3. сыналган; *искушённый в любви* — мәхәббәттә сыналган.

**ИСЛА'М** *м. мн.* нет, *книж.* — ислам, ислам дине, мөселман дине.

**ИСЛА'НДЕЦ** *м.* — исландияле.

**ИСЛА'НДКА** *ж.* — исландияле хатын-кыз.

**ИСЛА'НДЦЫ** *мн.* — исландиялеләр, Исландия халкы.

**ИСПА'ИВАТЬ** *несов. обл.* — к. испоить.

**ИСПА'КОСТИТЬ** *сов., простореч. вульг.* — 1. шакшылау, шакшылап бетерү, бик нык пычрату, пычратып бетерү; *испакостить новую посуду* — яңа савытны пычратып бетерү; 2. *перен.* бозып бетерү, эштән чыгару; *испакостить комнату плохими обоями* — бүлмәне начар обой ябыштырып эштән чыгару.

**ИСПА'КОСТИТЬСЯ** *сов., простореч. вульг.* — 1. шакшылану, шакшыланып бетү, пычрану, пычранып бетү; *всё пальто испакостилось* — бөтен пальтом пычранып беттe; 2. *перен.* бозылу, тәртипсезләнеп бетү; *мальчик совсем испакостился* — малай бөтенләй бозылды.

**ИСПА'НСКИЙ** — 1. испан...-ы; *испанский язык* — испан теле; *испанская литература* — испан әдәбияты; 2. Испания...-ы; *испанское правительство* — Испания хөкүмәте.

**ИСПА'НЦЫ** *мн.* — испаннар, Испания халкы.

**ИСПАРЕ'НИЕ** *ср. книж.* — 1. *только ед., спец.* парга әйләнү, парга әверелү; парга әйләндерү, парга әвереллерү; *испарение жидкостей* — сыекчаларны парга әйләндерү, сыекчаларның парга әйләнүе; 2. пар, бу; *вредные испарения* — зарарлы парлар.

**ИСПА'РИНА** *ж. мн.* нет — тир; *покрыться испариной* — тир белән каплану, тиргә бату.

**ИСПАРИ'ТЕЛЬ** *м. физ. тех.* — парга әйләндергеч (сыекчаларны парга әйләндерү приборы).

**ИСПАРИ'ТЬ** *сов. книж. спец.* — парга әверелдерү, парга әйләндерү; *испарить жидкость* — сыекчаны парга әйләндерү.

**ИСПАРИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. *книж. спец.* парга әйләнү, парга әверелү, парга чыгып бетү, парга очып бетү; *вода испарилась* — су парга әйләнеп беткән; 2. *перен. разг. фам.* (*исчезнуть*) сиздермичә китеп бару, югалу, сызу, шылу, таю, шыпырт кына юк булу, юкка чыгу.

**ИСПАРЯ'ЕМОСТЬ** *ж. мн.* нет, *физ.* — парга әйләнүчәнлек.

**ИСПАРЯ'ТЬ** *несов.* — к. испарить.

**ИСПАРЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. испариться; 2. *страд.* парга әверелдерелү, парга әйләндерелү.

**ИСПАСКУ'ДИТЬ** *сов. простореч. вульг.* — шакшылап бетерү, әшәкеләп бетерү, эштән чыгару.

**ИСПАСКУ'ДИТЬСЯ** *сов. простореч. вульг.* — шакшыланып бетү, шакшыланып бозылып бетү, әшәкеләнеп бетү, эштән чыгу.

**ИСПАХА'ТЬ** *сов. разг.* — сөреп бетерү, сөреп чыгу; *испахал всё поле* — бөтен басуны сөреп бетерде (сөреп чыкты).

**ИСПА'ХИВАТЬ** *несов.* — к. испахать.

**ИСПА'ХИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — сөрелеп бетү.

**ИСПА'ЧКАТЬ** *сов.* — буяп бетерү, пычратып бетерү; *испачкать одежду* — киемне пычратып бетерү.

**ИСПА'ЧКАТЬСЯ** *сов. разг.* — буялып бетү, пычранып бетү, буялып пычранып бетү; *испачкаться чернилами* — карага буялып (пычранып) бетү.

**ИСПАЯ'СНИЧАТЬСЯ** *сов. разг.* — шамакайланып бетү.

**ИСПЕПЕЛИ'ТЬ** *сов. книж. ритор.* — 1. яндырып бетерү, көлгә әйләндерү, көл итү; *война испепелила множество цветущих селений* — сугыш гөрләп торган күп кенә авылларны көлгә әйләндерде; 2. *перен.* газаплау, хәлсезләндерү, җәфалап бетерү, көйдерү, яндыру.

**ИСПЕПЕЛИ'ТЬСЯ** *сов. книж. ритор.* — янып бетү, көлгә әйләнү, көл булу.

**ИСПЕПЕЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. испепелить.

**ИСПЕПЕЛЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. испепелиться; 2 *страд.* көлгә әйләндерелү.

**ИСПЕСТРИ'ТЬ** *сов. разг.* — чуарлап бетерү; *испестрил стены картинками* — стенаны рәсемнәр белән чуарлап бетерде.

**ИСПЕСТРЯ'ТЬ** *несов.* — к. испестрить.

**ИСПЕСТРЯ'ТЬСЯ** *несов. страд. разг.* — чуарлап бетерелү.

**ИСПЕЧЁННЫЙ** — пешерелгән (икмәк). ◇ **Вновь испечённый** *разг. шутл.* — яңа

гына эшли башлаган; *вновь испечённый инженер* — яңа гына эшли башлаган инженер.

**ИСПЕ'ЧЬ** *сов.* — пешерү, пешереп бетерү (икмәкне).

**ИСПЕ'ЧЬСЯ** *сов.* — пешү, пешеп бетү, пешеп житү (икмәк).

**ИСПЕЩРИ'ТЬ** *сов. книж.* — чуарлап бетерү; *испещрить стол чернильными пятнами* — өстәлне кара таплары белән чуарлап бетерү; *испещрить поля книги заметками* — китап битенең кырыйларын искәрмәләр белән чуарлап бетерү.

**ИСПЕЩРЯ'ТЬ** *несов.* — к. испещрить.

**ИСПЕЩРЯ'ТЬСЯ** *несов. страд. книж.* — чуарлап бетерелү.

**ИСПИВА'ТЬ** *несов.* — к. испить.

**ИСПИВА'ТЬСЯ** *несов.* — эчелеп бетү.

**ИСПИ'ЛИВАТЬ** *несов.* — к. испилить.

**ИСПИ'ЛИВАТЬСЯ** *несов. спец.* — 1. к. испилиться; 2. *страд.* кисеп бетерелү; үтмәсләндерелү, үтмәсләндереп бетерелү.

**ИСПИЛИ'ТЬ** *сов.* — 1. кисеп бетерү, кисүгә тотып бетерү; *испилил все доски, а толку не получилось* — барлык такталарны кисеп бетердем, ләкин бер мәгънә дә чыкмады; 2. *спец.* (*о пиле*) күп кисеп үтмәсләү, үтмәсләндерү, үтмәсләп бетерү.

**ИСПИЛИ'ТЬСЯ** *сов. спец.* — үтмәсләнеп бетү, кыршылып бетү; *пила совсем испилилась* — пычкы бөтенләй үтмәсләнеп беткән.

**ИСПИСА'ТЬ** *сов.* — 1. (*заполнить писанием*) язып бетерү, язгалап бетерү, язып тутыру; 2. *разг.* (*истратить*) язуга тотып бетерү (мәсәлән, карандашны, дәфтәрне, кәгазьне).

**ИСПИСА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. яза-яза яраксызга әйләнү (каләм, карандаш турында); *эти перья совсем исписались* — бу каләмнәр бөтенләй яраксызга әйләнгәннәр; 2. (*о писателе*) язучылык сәләтен югалту.

**ИСПИ'СЫВАТЬ** *несов.* — к. исписать.

**ИСПИТО'Й** *разг.* — ябык, арык, чандыр, йончыган.

**ИСПИ'ТЬ** *сов.* — 1. *обл. простореч.* эчү, эчеп алу; 2. *книж. ритор.* баштан кичерү, тату; *испить горькую чашу страданий* — дөньяның ачысын-төчесен тату.

**ИСПЛА'ВАТЬ** *сов. разг.* — аркылыга-буйга йөзеп чыгу; *за свою долгую службу капитан исплавал много морей* — үзенең озак еллар хезмәт итү дәверендә капитан күп диңгезләрне аркылыга-буйга йөзеп чыккан (күп диңгезләрне кичкән, гизгән).

**ИСПЛЕВА'ТЬ** *сов. простореч.* — төкереп пычратып бетерү.

**ИСПЛЁВЫВАТЬ** *несов. простореч.* — к. исплевать.

**ИСПЛУТА'ТЬ** *сов. обл.* — адашып йөрү, йөреп чыгу.

**ИСПОВЕ'ДАНИЕ** *ср.* — 1. к. исповедовать 2, 3; 2. дин.

**ИСПОВЕ'ДАТЬ** *сов.* и *несов.* — к. исповедовать 1, 2, 3.

**ИСПОВЕ'ДАТЬСЯ** *сов.* — к. исповедоваться 1, 2.

**ИСПОВЕ'ДОВАТЬ** *сов.* и *несов.* — 1. *церк.* тәүбә иттерү; 2. *перен. разг. шутл.* (*расспрашивать, стараясь узнать*) сораштыру, сорашып белергә тырышу; 3. сөйләп бирү; *исповедовать другу свои задушевные мысли* — дустыңа үзеңнең эч серләреңне сөйләп бирү; 4. ...динен тоту, ...диненә ышану; *исповедовать мусульманство* — ислам динен тоту, ислам диненә ышану.

**ИСПОВЕ'ДОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов.* — 1. *церк.* тәүбә итү; 2. *разг. шутл.* ачыктан-ачык сөйләп бирү.

**ИСПОВЕ'ДЫВАТЬ** *несов.* — к. исповедовать.

**ИСПОВЕ'ДЫВАТЬСЯ** *несов.* — к. исповедоваться.

**И'СПОВЕДЬ** *ж.* — 1. *церк.* тәүбә; 2. *книж.* чын күңелдән әйтеп бирү, чын күңелдән тану.

**ИСПОВЕ'СНИЧАТЬСЯ** *сов. разг. фам.* — шуклыкның чигенә житү, эшлексезгә әверелү.

**ИСПОГА'НИВАТЬ** *несов. простореч. вульг.* — к. испоганить.

**ИСПОГА'НИВАТЬСЯ** *несов. простореч. вульг.* — 1. к. испоганиться; 2. *страд.* шакшылап бетерелү, пычратып бетерелү.

**ИСПОГА'НИТЬ** *сов. простореч. вульг.* — 1. шакшылау, шакшылап бетерү, пычратып бетерү; *испоганил чистое ведро* — чиста чиләкне шакшылаган, шакшылап бетергән; 2. бозу; *такая погода испоганила ему всё настроение* — мондый һава аның кәефен бөтенләй бозды.

**ИСПОГА'НИТЬСЯ** *сов. простореч. вульг.* — 1. (*стать грязным*) шакшыланып бетү, пычранып бетү; 2. бозылу, кырылу; *испоганилось всё настроение* — бөтен кәефем кырылды.

**ИСПО'Д** *м. обл.* — ас як, эчке як, тискәре як (мәсәлән, материянең тискәре ягы).

**И'СПОДВОЛЬ** *нареч. разг.* — акрынлап, ашыкмыйча гына, әзләп-әзләп; *исподволь он стал заниматься приготовлением к отъезду* — ул акрынлап юлга хәзерләнә башлады.

**ИСПО'ДКА** *ж. обл.* — к. испод.

**ИСПО'ДЛИЧАТЬСЯ** *сов. разг.* — кабахәт кешегә әверелү, кабахәтлекнең чигенә житү, әшәкелекнең чигенә житү.

**ИСПОДЛО'БЬЯ** *нареч.* — маңгай астыннан, каш жыерып, яратмыйча, кырын (карау турында).

**ИСПО'ДНИ'ЗУ** *нареч. разг.* — астан.

**ИСПО'ДНИЙ** *разг. устар. обл.* — эчке (кием турында); *исподняя рубашка* — эчке күлмәк. ◇ **Исподняя сторона** *обл.* — тискәре ягы, эчке ягы.

**ИСПО'ДНИК** *м.* — 1. *обл.* эчлек, астарлык, астар, аслык; 2. *тех.* кечкенә сандал (тимер чүкү өчен); 3. *обл. только мн.* ыштан.

**ИСПО'ДНИЦА** *ж. обл.* — эчке күлмәк, бельё (күбесенчә хатын-кыз бельёсы).

**ИСПОДТИШКА'** *нареч. разг.* — астыртын, яшертен; *смеяться исподтишка* — астыртын көлү; *действовать исподтиш-*

*ка* — астыртын хәрәкәт итү; яшертен хәрәкәт итү.

**ИСПОИ'ТЬ** *сов. обл.* — эчереп бетерү; *испоил лошадям два ведра воды* — атларга ике чиләк су эчереп бетердем.

**ИСПОКО'Н**: испокон веку или испокон веков *разг. просторец.* — күптәннән, борын-борыннан, элек-электән, мәңге; *испокон веку уж так ведётся* — борын-борыннан инде шулай килә.

**ИСПОЛА'ТЬ** *межд. ритор. устар.* — дан; *исполать вам, доблестные воины!* — дан сезгә, батыр сугышчылар!

**ИСПО'ЛЗАТЬ** *сов. разг.* — шуышып йөреп чыгу, үрмәләп йөреп чыгу.

**ИСПОЛИ'Н** *м. книж.* — 1. (*богатырь, великан*) баһадир, алып, гаять зур кеше; 2. *перен. ритор.* зур кеше, даһи; *исполин науки* — фән даһие, бик зур галим.

**ИСПОЛИ'НСКИЙ** *книж.* — 1. бик зур, гаять озын, гадәттән тыш зур, гигант (гәүдәле); *человек исполинского роста* — бик зур гәүдәле кеше; 2. *перен.* гадәттән тыш зур; *исполинский размах* — гадәттән тыш зур колач.

**ИСПОЛКО'М** (исполнительный комитет) *м.* — башкарма комитет.

**ИСПОЛНЕ'НИЕ** *ср. книж.* — 1. башкару, үтәү; башкарылу, үтәлү; 2. үтәлеш; *работа отличается изящным исполнением* — эш оста үтәлеше белән аерылып тора; *проверка исполнения* — үтәлешне тикшерү; 3. *канц.* копия (учреждение тарафыннан җибәрелгән кәгазьнең күчермәсе). ◇ **Привести в исполнение** *книж.* — үтәү, башкару. **В исполнение или во исполнение** *офиц.* — тормышка ашыру максаты белән, үтәү йөзеннән, үтәү теләге белән.

**ИСПО'ЛНЕННЫЙ** — 1. башкарылган, үтәлгән; *исполненное решение* — үтәлгән карар; 2. *книж.* тулган, тулы; ...-лы; *песня, исполненная радости* — шатлык белән тулы җыр, шатлыклы җыр.

**ИСПОЛНИ МОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — үтәлерлек булу, башкарылырлык булу.

**ИСПОЛНИ'МЫЙ** *книж.* — үтәлерлек, башкарылырлык, тормышка ашырырлык; *исполнимое желание* — үтәлерлек теләк.

**ИСПОЛНИ'ТЕЛЬ** *м.*, **ИСПОЛНИ'ТЕЛЬНИЦА** *ж. книж.* — башкаручы, үтәүче; *исполнитель приказаний* — боерыкларны үтәүче; *исполнитель народных песен* — халык җырларын башкаручы. ◇ **Судебный исполнитель** *офиц. юр.* — суд исполнителе (суд карарын тормышка ашыручы).

**ИСПОЛНИ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — тыңлаучанлык, үтәүчәнлек, башкаручанлык.

**ИСПОЛНИ'ТЕЛЬНЫЙ** — 1. *книж. офиц.* башкаручы, башкарма, тормышка ашыручы, башкара торган; *исполнительные органы* — башкаручы органнар; *исполнительный комитет* — башкарма комитет; 2. тыңлаучан, эшне үтәүчән, яхшы башкаручан; *исполнительный человек* — тыңлаучан (эшне үтәүчән) кеше. ◇ **Исполнительный лист** *офиц.* — исполнительный лист (суд карарын үтәү турында суд приказы).

**ИСПОЛНИ'ТЕЛЬСКИЙ** — башкаручылар ...-ы, башкаручы...-ы; башкару...-ы; *исполнительский класс консерватории* — консерваториянең башкаручылар классы; *исполнительское искусство* — башкару сәнгате.

**ИСПО'ЛНИТЬ** *сов.* — 1. башкару, үтәү, тормышка ашыру, җиренә җиткерү; *исполнить приказ* — приказны үтәү; 2. *искус.* башкару, уйнау; *исполнить роль* — роль башкару; 3. *книж. устар.* рухландыру, тудыру, салу; *исполнить сердце надеждой* — күңелдә өмет тудыру, күңелгә өмет салу.

**ИСПО'ЛНИТЬСЯ** *сов.* — 1. үтәлү, тормышка ашу; *желание моё исполнилось* — минем теләгем тормышка ашты; 2. үтү, тулу, булу; *сыну исполнилось семь лет* — улыма җиде яшь тулды; *уже пять лет исполнилось с тех пор, как мой сын уехал* — минем улым киткәнгә биш ел булды инде; 3. *книж. устар.* тулу; *душа моя исполнилась радости* — күңелем шатлык белән тулды.

**ИСПОЛНЯ'ТЬ** *несов.* — к. исполнить.

**ИСПОЛНЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. исполниться; 2. *страд.* үтәлү, тормышка ашырылу, җиренә җиткерелү.

**ИСПОЛО'ВНИК** *м. с.-х. истор.* — к. испольщик.

**ИСПОЛО'ВНИЧАТЬ** *несов. с.-х. истор.* — к. испольничать.

**ИСПОЛО'ВНИЧЕСТВО** *ср. мн.* нет — к. испольничество.

**ИСПОЛОСОВА'ТЬ** *сов. разг.* — 1. телгәләп бетерү; *исполосовать материю* — материяне телгәләп бетерү; 2. *(избить бичом)* камчы (чыбыркы) белән кыйнау, яру.

**И'СПОЛУ** *нареч. с.-х., истор.* — уртакка, уртагыннан; *обрабатывать землю исполу* — җирне уртакка (уңышның яртысын җир хуҗасына бирү шарты белән) эшкәртү.

**ИСПО'ЛЬЗОВАНИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — файдалану, куллану; *использование электричества* — электрдан файдалану.

**ИСПО'ЛЬЗОВАТЬ** *сов.* и *несов., книж.* — файдалану, куллану; *использовать опыт передовиков* — алдынгылар тәҗрибәсеннән файдалану, эштә алдынгылар тәҗрибәсен куллану.

**ИСПО'ЛЬЗОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. страд.* — файдаланылу, кулланылу.

**ИСПО'ЛЬНИЧАТЬ** *несов. с.-х. истор.* — уртакка эшләү.

**ИСПО'ЛЬНИЧЕСТВО** *ср. мн.* нет, *с.-х. истор.* — уртакка эшләү.

**ИСПО'ЛЬНЫЙ** *с.-х. истор.* — уртак, уртакка эшләнә торган; *испольное хозяйство* — уртак хуҗалык.

**ИСПО'ЛЬЩИК** *м. с.-х. истор.* — уртакка эшләүче (крестьян).

**ИСПО'ЛЬЩИНА** *ж. мн.* нет, *с.-х. истор.* — испольщина, уртакка эшләү (җир арендасының бер төре; җир хакы хуҗага акчалата түгел, бәлки уңышның яртысы белән түләүдән гыйбарәт булган аренда төре).

**ИСПОРО'ТЬ** *сов. простореч.* — сүтеп бетерү (тегелгән әйберне).

**ИСПО'РТИТЬ** *сов.* — бозу, бозып бетерү, эштән чыгару, харап итү; *испортить механизм* — механизмны бозу; *испортить отношения* — мөнәсәбәтләрне (араны) бозу.

**ИСПО'РТИТЬСЯ** *сов.* — бозылу, эштән чыгу; *часы испортились* — сәгать бозылды.

**ИСПО'РЧЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет — бозыклык, бозылганлык.

**ИСПО'РЧЕННЫЙ** — 1. бозылган, бозык, эштән чыккан, ватык, ватылган; *испорченный замок* — ватык (бозылган) йозак; 2. бозык, эштән чыккан, әхлаксыз; *испорченный характер* — бозык характер; *испорченный человек* — бозык кеше, әхлаксыз кеше.

**ИСПОСТИ'ТЬСЯ** *сов. разг. фам.* — ураза тотып хәлдән таю.

**ИСПОХА'БИТЬ** *сов. простореч. вульг.* — шакшылап бетерү, пычратып бетерү; бозып бетерү.

**ИСПОХА'БИТЬСЯ** *сов. простореч. вульг.* — шакшыланып бетү, пычранып бетү; бозылып бетү.

**ИСПОХА'БНИЧАТЬСЯ** *сов. простореч. вульг.* — оятсызга әйләнү, оятсызга әверелү, оятсызлыкның чигенә җитү.

**ИСПО'ШЛИТЬ** *сов. разг.* — кабахәт рәвештә бозу, әшәкеләндерү; *испошлить чьи-н. слова* — кемнең дә булса сүзләрен кабахәт рәвештә бозу.

**ИСПО'ШЛИТЬСЯ** *сов. разг.* — бозылу, бозыклыкның чигенә җитү, кабахәткә әйләнү, әшәкеләнү.

**ИСПРАВИ'МЫЙ** — төзәлерлек, төзәтелерлек, төзәтергә мөмкин булган; *эта беда ещё исправимая* — бу бәлане әле төзәтергә мөмкин, бу бәла әле төзәтелерлек.

**ИСПРАВИ'ТЕЛЬ** *м. книж.* — төзәтүче.

**ИСПРАВИ'ТЕЛЬНО-ТРУДОВО'Й** *офиц.* — хезмәт белән төзәтү...-ы; *исправительно-трудовые дома* — хезмәт белән төзәтү йортлары.

**ИСПРАВИ'ТЕЛЬНЫЙ** — төзәтү...-ы; төзәтә торган; *исправительные меры* — төзәтү чаралары.

**ИСПРА'ВИТЬ** *сов.* — төзәтү; *исправить замок* — йозакны төзәтү; *исправить ошибку* — хатаны төзәтү. ◇ Горбатого одна могила исправит *пословица* — бөкрене кабер генә төзәтер.

**ИСПРА'ВИТЬСЯ** *сов.* — төзәлү.

**ИСПРАВЛЕ'НИЕ** *ср. книж.* — 1. к. исправить и исправиться; 2. (*поправка*) төзәтмә, төзәтү; *внести исправление в статью* — мәкаләгә төзәтмә (төзәтү) кертү.

**ИСПРАВЛЯ'ТЬ** *несов.* — 1. к. исправить; 2. *офиц.* үтәү, башкару, алып бару; *исправлять обязанности секретаря* — секретарьлык вазифасын үтәү.

**ИСПРАВЛЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. исправиться; *дети исправляются* — балалар төзәләләр; 2. *страд.* төзәтелү.

**ИСПРА'ВНИК** *м. истор.* — исправник (революциягә кадәр өяз полициясе начальнигы).

**ИСПРА'ВНИЦА** *ж. разг. доревол.* — исправник хатыны.

**ИСПРА'ВНИЧЕСКИЙ** и **ИСПРА'ВНИЧИЙ** *доревол.* — исправник...-ы; исправникларча...; *исправничий дом* — исправник йорты; *исправнические выходки* — исправникларча кыланулар.

**ИСПРА'ВНОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. төзеклек; *исправность инструментов* — инструментларның төзеклеге; 2. (*исполнительность*) үтәүчәнлек, тыңлаучанлык.

**ИСПРА'ВНЫЙ** — 1. төзек, җитеш, бетәү; *исправный мотор* — төзек мотор; 2. (*аккуратный, исполнительный*) үтәүчән, тыңлаучан, күндәм.

**ИСПРАЖНЕ'НИЕ** *ср. книж.* — 1. к. испражниться; 2. *только мн.* тизәк, тәрәт.

**ИСПРАЖНИ'ТЬСЯ** *сов. книж.* — тышка чыгу, тәрәт итү, бушану.

**ИСПРАЖНЯ'ТЬСЯ** *несов. книж.* — к. испражниться.

**ИСПРА'ШИВАТЬ** *несов. офиц. канц.* — 1. к. испросить; 2. артыннан йөрү, сорау, үтенү.

**ИСПРА'ШИВАТЬСЯ** *несов. офиц. канц.* — сорап алыну, артыннан йөреп алыну.

**ИСПРО'БОВАТЬ** *сов. разг.* — 1. сынау, сынап карау; *испробовать новый инструмент* — яңа инструментны сынау; 2. сынап карау, татып карау; *он испробовал много профессий* — ул бик күп профессияне сынап карады (татып карады).

**ИСПРОСИ'ТЬ** *сов. офиц. канц.* — сорап алу, артыннан йөреп алу; *испросить аванс* — аванс сорап алу.

**ИСПРЫ'СКАТЬ** *сов. простореч.* — 1. чәчрәтеп бетерү, чәчрәтеп тутыру; *испрыскать стены водой* — стеналарга су чәчрәтеп бетерү; 2. сибеп бетерү, бөркеп бетерү; *испрыскать все духи* — барлык исле майны сибеп бетерү.

**ИСПРЫ'СКИВАТЬ** *несов.* — к. испрыскать.

**ИСПРЯМИ'ТЬ** *сов. разг.* — төзәйтү, турайту; *испрямить гвоздь* — кадакны турайту.

**ИСПРЯМИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — тураю, төзәю.

**ИСПРЯМЛЯ'ТЬ** *несов. разг.* — к. испрямить.

**ИСПРЯМЛЯ'ТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. к. испрямиться; 2. *страд.* төзәйтелү, турайтылу.

**ИСПРЯ'СТЬ** *сов. обл.* — эрләп бетерү (эрләүгә тотып бетерү); *старуха испряла весь лён* — карчык бөтен җитенне эрләп бетерде.

**ИСПРЯ'СТЬСЯ** *сов. обл.* — эрләнеп бетү, эрләүгә тотылып бетү.

**ИСПУ'Г** *м.* — курку, куркыну; шүрләү, кот очу, өркү (күбрәк хайваннар турында).

**ИСПУ'ГАННЫЙ** — 1. курыккан, куркытылган, куркынган; *испуганный ребёнок* — куркытылган бала; *испуганные люди* — куркынган кешеләр; 2. куркулы; *испуганное лицо* — куркулы кыяфәт.

**ИСПУГА'ТЬ** *сов.* — куркыту, котын очыру, котын алу; өркетү.

**ИСПУГА'ТЬСЯ** *сов.* — курку, кот чыгу, кот очу, өркү.

**ИСПУЖА'ТЬ** *сов. обл.* — к. испугать.

**ИСПУЖА'ТЬСЯ** *сов. обл.* — к. испугаться.

**ИСПУСКА'ТЬ** *несов. книж.* — к. испустить.

**ИСПУСКА'ТЬСЯ** *несов. книж.* — чыгарылу, таралу (тавыш, ис).

**ИСПУСТИ'ТЬ** *сов. книж.* — чыгару, аңкыту, тарату. ◇ **Испустить крик** — кычкырып җибәрү. **Испустить дух** — җан бирү, үлү.

**ИСПЫТА'НИЕ** *ср. книж.* — 1. сынау, сынап карау, тикшерү; *испытание двигателя* — двигательны сынап карау; 2. *офиц.* сынау; *приёмные испытания* — кабул итү сынаулары; 3. кичереш, бәхетсезлек; *тяжёлые испытания* — авыр кичерешләр.

**ИСПЫ'ТАННЫЙ** *книж.* — сынап каралган, сыналган, тикшерелгән; *машина, испытанная механиком* — механик тарафыннан тикшерелгән (сыналган) машина; *испытанный друг* — сыналган дус.

**ИСПЫТА'ТЕЛЬНЫЙ** *книж. офиц.* — сынау...-ы; *испытательный срок* — сынау срогы; *испытательная комиссия* — сынау комиссиясе (сынау өчен билгеләнгән комиссия).

**ИСПЫТА'ТЬ** *сов. книж.* — 1. сынау, тикшерү, сынап карау; *испытать нового работника* — яңа эшчене сынау (сынап карау); 2. кичерү, баштан кичерү, тату; *испытать несчастье* — бәхетсезлек кичерү; 3. *(почувствовать)* тою.

**ИСПЫТУ'ЕМЫЙ** *книж. офиц.* — 1. сынала торган, тикшерелә торган; *испытуемые ученики* — сынала торган укучылар; 2. *в знач. сущ.* — сыналучы; *это отделение для испытуемых* — бу бүлек сыналучылар өчен.

**ИСПЫТУ'ЮЩЕ** *нареч.* — текәп, текәлеп, сынаулы; *испытующе посмотреть* — текәп карау, сынаулы карау.

**ИСПЫТУ'ЮЩИЙ** *книж.* — сынаулы, текәүле; *испытующий взгляд* — сынаулы караш.

**ИСПЫ'ТЫВАТЬ** *несов. книж.* — к. испытать.

**ИСПЫ'ТЫВАТЬСЯ** *несов. страд. книж.* — сыналу, тикшерелү.

**ИСПЯТНА'ТЬ** *сов. разг.* — таплап бетерү, тапландырып бетерү (мәсәлән, май таплары белән).

**ИСПЯТНА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — тапланып бетү.

**ИССА'ЛИВАТЬ** *несов. просторечь.* — к. иссалить.

**ИССА'ЛИВАТЬСЯ** *несов. просторечь.* — 1. к. иссалиться; 2. *страд.* майга буяп каешландырып бетерелү.

**ИССА'ЛИТЬ** *сов. просторечь.* — майга буяп каешландырып бетерү; *иссалить рукава* — җиңнәрне майга буяп каешландырып бетерү.

**ИССА'ЛИТЬСЯ** *сов. просторечь.* — майга буялып каешланып бетү.

**ИССА'СЫВАТЬ** *несов. просторечь.* — к. иссосать.

**ИССВЕ'РЛИВАТЬ** *несов. разг.* — к. иссверлить.

**ИССВЕ'РЛИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. к. иссверлиться; 2. *страд.* бораулый-бораулый эштән чыгарылу.

**ИССВЕРЛИ'ТЬ** *сов. разг.* — бораулап чокырландырып бетерү.

**ИССВЕРЛИ'ТЬСЯ** *сов. разг. спец.* — бораулый-бораулый бозылу, бораулый-бораулый эштән чыгу (инструмент турында).

**ИССЕКА'ТЬ** *несов.* — к. иссечь.

**ИССЕКА'ТЬСЯ** *несов. разг.* — к. иссечься.

**И'ССЕРА** *нареч.* — соргылт-; *иссера-голубой* — соргылт-зәңгәр.

**ИССЕ'ЧЬ** *сов.* — 1. *устар.* чокып ясау, кырып ясау; *иссечь статую* — сынны (статуяны) чокып ясау; 2. кискәләп бетерү, тураклап бетерү; *иссечь мечом* — кылыч белән кискәләп бетерү; 3. *(высечь розгами) устар.* суктыру, чыбык белән суктыру, камчы белән суктыру.

**ИССЕ'ЧЬСЯ** *сов. обл. устар.* — коелу (чәч, йон турында).

**И'ССИЗА** *нареч.* — күгелҗем-; *иссиза-голубой* — күгелҗем-зәңгәр.

**ИССИНИ'ТЬ** *сов. просторечь.* — синькалауга тотып бетерү.

**ИССИНИ'ТЬСЯ** *сов. просторечь.* — синькалауга тотылып бетү.

**И'ССИНЯ** *нареч.* — зәңгәрсу-; *иссиня-чёрный* — зәңгәрсу-кара.

**ИССЛЕДИ'ТЬ** *сов. просторечь.* — таптап бетерү, таптап пычратып бетерү; *исследили только что вымытый пол* — әле генә юган идәнне таптап бетергәннәр.

**ИССЛЕ'ДОВАНИЕ** *ср. книж.* — 1. тикшерү, тикшеренү; *научное исследование* — фәнни тикшеренү; 2. фәнни хезмәт, фәнни әсәр; *исследование по русскому языку* — рус теле буенча фәнни хезмәт.

**ИССЛЕ'ДОВАТЕЛЬ** *м.*, **ИССЛЕ'ДОВАТЕЛЬНИЦА** *ж. книж.* — тикшеренүче, фәнни тикшеренүче, тикшеренү эшләре алып баручы.

**ИССЛЕ'ДОВАТЕЛЬСКИЙ** *книж.* — тикшеренү...-ы; *исследовательские работы* — тикшеренү эшләре; *исследовательский институт* — тикшеренү институты.

**ИССЛЕ'ДОВАТЬ** *сов. и несов. книж.* — 1. тикшерү, фәнни тикшерү; *исследовать законы природы* — табигать законнарын тикшерү; 2. карау, тикшереп карау, тикшереп карап чыгу; *исследовать больного* — авыруны карау; *исследовать всё побережье* — бөтен яр буен тикшереп карап чыгу.

**ИССЛЕ'ДОВАТЬСЯ** *сов. и несов. страд. книж.* — 1. тикшерелү, фәнни тикшерелү; 2. каралу, карап чыгылу.

**ИССЛЕ'ЖИВАТЬ** *несов. просторечь.* — к. исследить.

**ИССЛЕ'ЖИВАТЬСЯ** *несов. просторечь.* — таптап бетерелү, тапталып пычратып бетерелү.

**ИССЛЮ'НИВАТЬ** *несов. просторечь.* — к. иссслюнить.

**ИССЛЮНИ'ТЬ** *сов. простореч.* — селәгәйләндереп бетерү, селәгәйгә буяп бетерү, селәгәйгә пычратып бетерү.

**ИССЛЮНЯ'ВИТЬ** *сов. простореч.* — к. исслюнить.

**ИССОЛИ'ТЬ** *сов. разг.* — тозлауга тотып бетерү.

**ИССОСА'ТЬ** *сов. простореч.* — имеп хәлсезләндереп бетерү, имеп йончытып бетерү; имеп бозып бетерү, имеп эштән чыгару.

**ИССО'ХНУТЬ** *сов.* — 1. кибеп бетү; *пруд иссох* — буа кибеп беткән; 2. кору, корып бетү; *деревья иссохли* — агачлар корып беттеләр; 3. *разг.* кору; *рука иссохла* — кул корыды; 4. *перен. разг.* ябыгу, ябыгып бетү, йончу, хәлсезләнү, кибү; *за время своей болезни он совсем иссох* — авыруган вакытында ул бөтенләй кипте (йончыды).

**И'ССТАРИ** *нареч.* — борынгыдан, күптәннән, элекедән.

**ИССТЕГА'ТЬ** *сов. простореч.* — 1. *(избить розгами)* камчылау, суктыру, камчылап бетерү; 2. камчылый-камчылый туздыру, камчылый-камчылый туздырып бетерү (камчыны, чыбыркыны).

**ИССТЕГА'ТЬСЯ** *сов. простореч.* — камчылый-камчылый тузып бетү (камчы, чыбыркы турында).

**ИССТЕЛИ'ТЬ** *сов. простореч.* — к. изостлать.

**ИССТИЛА'ТЬ** *несов.* — к. изостлать.

**ИССТИЛА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — җәелү, түшәлү.

**ИССТИРА'ТЬ** *сов. разг.* — кер ууга тотып бетерү (мәсәлән, сабынны).

**ИССТИРА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — кер ууга тотылып бетү.

**ИССТИ'РЫВАТЬ** *несов. разг.* — к. исстирать.

**ИССТИ'РЫВАТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. к. исстираться; 2. *страд.* кер ууга тотып бетерелү.

**ИССТРАДА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — җәфаланып бетү, газапланып бетү, йөдәү; *она исстрадалась в одиночестве* — ул ялгызлыкта җәфаланып беткән.

**ИССТРА'ЧИВАТЬ** *несов. простореч. порт.* — к. исстрочить.

**ИССТРА'ЧИВАТЬСЯ** *несов. простореч. порт.* — к. исстрочиться.

**ИССТРЕ'ЛИВАТЬ** *несов.* — к. исстрелять.

**ИССТРЕ'ЛИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. *(израсходоваться)* атылып бетү, атуга тотылып бетү (патроннар турында); 2. *разг. (испещряться)* атудан тишкәләнеп бетү.

**ИССТРЕЛЯ'ТЬ** *сов.* — 1. атып бетерү, атуга тотып бетерү; *исстрелять патроны* — патроннарны атып бетерү; 2. атып тишкәләп бетерү; *исстрелять всю стену* — бөтен стенаны атып тишкәләп бетерү.

**ИССТРОГА'ТЬ** *сов. спец.* — 1. *(израсходовать)* струклауга тотып бетерү; 2. *(об инструменте)* струклап үтмәсләп бетерү.

**ИССТРОГА'ТЬСЯ** *сов. спец.* — 1. *(израсходоваться при строгании)* струклауга тотылып бетү; 2. *(об инструменте)* струклап үтмәсләнеп бетү.

**ИССТРОЧИ'ТЬ** *сов.* — 1. *простореч. пренебр. (исписать)* язгалап ташлау, язгалап пычратып бетерү; 2. *порт. (истратить на вышивку в строчку)* чигүгә тотып бетерү.

**ИССТРОЧИ'ТЬСЯ** *сов. порт.* — чигүгә тотылып бетү.

**ИССТУПЛЕ'НИЕ** *ср. книж.* — ярсу, шашыну, чиктән чыгу; *своей назойливостью она его довела до исступления* — үзенең бәйләнчеклеге белән ул аны шашыну дәрәҗәсенә илтеп җиткерде.

**ИССТУПЛЁННЫЙ** *книж.* — ярсыган, шашынган, ярсулы, ачулы; *исступлённый человек* — ярсыган кеше, чиктән тыш ачуланган кеше; *исступлённое выступление* — ярсулы чыгыш.

**ИССУША'ТЬ** *несов.* — к. иссушить.

**ИССУША'ТЬСЯ** *несов. разг.* — к. иссушиться.

**ИССУШИ'ТЬ** *сов.* — 1. киптереп бетерү; *иссушить болото* — сазлыкны киптереп бетерү; *иссушили все собранные грибы* — җыелган гөмбәләрнең барысын да киптереп бетердек; 2. *перен.* ябыктырып бетерү, йончытып бетерү, хәлсезләндереп бетерү; *лихорадка иссушила больного* — бизгәк авыруны ябыктырып бетергән.

**ИССУШИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — кибү, кибеп җитү; *булка, изрезанная на сухари, хорошо иссушилась* — сохарига дип туралган булка яхшы кипкән.

**ИССЫХА'ТЬ** *несов.* — к. иссохнуть.

**ИССЯКА'ТЬ** *несов. книж.* — к. иссякнуть.

**ИССЯ'КНУТЬ** *сов.* — 1. кору, юкка чыгу, кибеп бетү, корып бетү; *источник иссяк* — чишмә корып беткән, кибеп беткән; 2. бетү; *деньги иссякли* — акча бетте; 3. *перен.* сүнү; *любовь постепенно иссякла* — мәхәббәт әкренләп сүнде.

**ИСТА'ИВАТЬ** *несов.* — к. истаять.

**ИСТА'ПЛИВАТЬ** *несов.* — к. истопить.

**ИСТА'ПЛИВАТЬСЯ** *несов.* — к. истопиться.

**ИСТА'ПТЫВАТЬ** *несов.* — к. истоптать.

**ИСТА'ПТЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. истоптаться; 2. *страд.* таптап пычратып бетерелү; киеп туздырып бетерелү (аяк киеме).

**ИСТАСКА'ТЬ** *сов. простореч.* — киеп туздыру, киеп туздырып бетерү, киеп искертеп бетерү.

**ИСТАСКА'ТЬСЯ** *сов. простореч.* — 1. киелеп тузып бетү, киелеп искереп бетү; 2. *перен. неодобр.* күп азып-тузып йөрүдән йончып бетү, хәлсезләнеп бетү.

**ИСТА'СКИВАТЬ** *несов. простореч.* — к. истаскать.

**ИСТА'СКИВАТЬСЯ** *несов. простореч.* — 1. к. истаскаться; 2. *страд.* киеп туздырып бетерелү.

**ИСТА'ЧИВАТЬ** *несов. спец.* — к. источить 1.

**ИСТА'ЧИВАТЬСЯ** *несов. спец.* — к. источиться

**ИСТА'ЯТЬ** *сов.* — 1. эреп бетү; *воск весь истаял* — балавыз бөтенләй эреп бетте; 2. *перен.* ябыгып бетү, сәламәтлекне югалту; *он совсем истаял от тоски* — ул сагыштан бөтенләй ябыгып беткән.

**ИСТЕКА'ТЬ** *несов. книж.*— к. истечь.

**ИСТЕ'КШИЙ** и **ИСТЁКШИЙ** — 1. *(о жидкости)* агып беткән; 2. *офиц.* үткән, узган; *истёкший год* — үткән ел.

**ИСТЕРЕ'ТЬ** *сов. разг.* — 1. уып бетерү, кырып бетерү; *истёр весь сыр на тёрке* — кыргычта барлык сырны (уып) кырып бетердем; 2. ышкый-ышкый бетерү; *истереть резинку* — ышкый-ышкый резинкәны бетерү. ◇ **Истереть в порошок** *разг.* — измәсен изү, тетмәсен тетү, кирәгеп бирү.

**ИСТЕРЕ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — (ышкылып) тузып бетү; *подошва истёрлась* — аяк киеменең табаны тузып беткән.

**ИСТЕРЗА'ТЬ** *сов. книж.*— 1. *(измучить терзаниями)* җәфалап бетерү, газаплап бетерү; *горе истерзало его* — аны кайгы газаплап бетергән; 2. *устар. (изорвать)* өзгәләп бетерү, теткәләп бетерү; *собаки истерзали его одежду* — этләр аның киемен өзгәләп бетерделәр.

**ИСТЕРЗА'ТЬСЯ** *сов. книж.* — газапланып бетү, җәфаланып бетү; *он истерзался в ожидании* — көтә-көтә ул газапланып бетте.

**ИСТЕ'РИК** *м.*— истерик, истерия белән авыручы кеше.

**ИСТЕ'РИКА** *ж.*— истерика (истерия нәтиҗәсендә бик каты көзән җыеру һәм тыела алмыйча елау дәрәҗәсенә җитү).

**ИСТЕРИ'ЧЕСКИЙ** *книж.* — истерик; *истерический припадок* — истерик һуш китү; *истерический смех* — истерик көлү.

**ИСТЕРИ'ЧКА** *ж.*— к. истерик.

**ИСТЕРИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— истериклык.

**ИСТЕРИ'ЧНЫЙ** — к. истерический.

**ИСТЕРИ'Я** *ж. мн.* нет, *мед.* — истерия (артык дәрәҗәдә тәэсиргә бирелүчәнлектән, ярсучанлыктан гыйбарәт булган нерв авыруы). ◇ **Военная истерия** *перен.* — хәрби истерия (империалистик илләрдә сугышка өндәү һәм шашынып коралланy).

**ИСТЕСА'ТЬ** *сов. разг.* — юнып бетерү (юнуга тотып бетерү); *доску истесал, а ничего не сделал* — тактаны юнып бетердем, ләкин бернәрсә дә ясамадым.

**ИСТЁСЫВАТЬ** *несов. разг.*— к. истесать.

**ИСТЁСЫВАТЬСЯ** *несов. страд. разг.* — юнылып бетү.

**ИСТЕ'Ц** *м. офиц.* —дәгъвачы (суд эшендә).

**ИСТЕЧЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — 1. *устар.* агып бетү; *истечение крови* — канның агып бетүе; 2. *офиц.* тулу, үтү, чыгу; *за истечением положенного времени председатель прервал речь оратора* — билгеләнгән вакыт үтү сәбәпле, председатель ораторның речен бүлде.

**ИСТЕ'ЧЬ** *сов. книж.*— 1. *устар. (о жидкости)* агып бетү; 2. *(о времени)* тулу, бетү, чыгу, үтү; *срок истёк* — срок тулды (чыкты, бетте). ◇ **Истечь кровью** *книж.*— кан түгү, күп кан югалту.

**И'СТИНА** *ж* — хакыйкать, дөреслек, чынлык; *стремление к истине лежит в основе научных исканий* — хакыйкатькә омтылыш фәнни эзләнүләрнең нигезендә ята; *соответствовать истине* — дөреслеккә туры килү, чыннан да шулай булу.

**И'СТИННО** *нареч.*— 1. *книж.* чын, чыннан да; *истинно великий человек* — чыннан да бөек кеше; 2. *в знач. ввод. сл.* дөрестән дә, чыннан да; *истинно, у нас осенью без галош нельзя* — чыннан да, көзен бездә галошсыз (йөрү) мөмкин түгел.

**И'СТИННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — дөреслек, хаклык, чынлык; *истинность этого известия* — бу хәбәрнең дөреслеге (чынлыгы).

**И'СТИННЫЙ** *книж.* — чын, дөрес, хак; *истинное сообщение* — дөрес хәбәр; *истинный друг* — чын дус.

**ИСТИРА'ТЬ** *несов. разг.*— к. истереть.

**ИСТИРА'ТЬСЯ** *несов. разг.* — к. истереться.

**ИСТИ'СКАТЬ** *сов. простореч.* — кысып изеп бетерү; кысып җәфалап бетерү.

**ИСТИ'СКИВАТЬ** *несов.*— к. истискать.

**ИСТИ'ЦА** *ж. офиц.*— к. истец.

**ИСТКА'ТЬ** *сов. книж. устар. обл.* — к. изоткать.

**ИСТЛЕВА'ТЬ** *несов. книж. устар. обл.*— к. истлеть.

**ИСТЛЕ'ТЬ** *сов.*— 1. череп бетү; *материя истлела* — материя череп беткән; 2. янып көлгә әйләнү, пыскып янып бетү; *последние угли истлели* — соңгы күмерләр пыскып янып беттеләр.

**И'СТОВО** *нареч. книж. устар.* — чын күңелдән, ихлас белән, җиренә җиткереп, бик тырышып.

**И'СТОВЫЙ** *книж. устар.*— чын күңелдән эшләнгән, ихлас белән эшләнгән, бик тырышып эшләнгән, җиренә җиткереп эшләнгән.

**ИСТО'К** *м. книж.*— 1. чыганак, су башы, елга башы, чишмә башы; 2. *перен.* башлангыч чор, баш, чыганак, башлангыч.

**ИСТОЛКА'ТЬ** *сов. просторечь.* — этептөртеп бетерү, этеп-төртеп хәлдән тайдыру.

**ИСТОЛКОВА'НИЕ** *ср. книж.*—1. к. истолковать; 2. *(объяснение)* аңлатма.

**ИСТОЛКОВА'ТЬ** *сов. книж.*— 1. аңлату, төшендерү, аңлатып бирү, төшендереп бирү; *неправильно истолковать закон* — законны ялгыш аңлатып (төшендереп) бирү; 2. *(понять)* аңлау, төшенү; *истолковать по своему* — үзенчә аңлау.

**ИСТОЛКОВА'ТЬСЯ** *сов. книж.* — аңлашылу, аңлашылып җитү.

**ИСТОЛКО'ВЫВАТЬ** *несов.* — к. истолковать.

**ИСТОЛКО'ВЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. истолковаться; 2. *страд.* аңлатылу, төшендерелү, аңлатып (төшендереп) бирелү.

**ИСТОЛО'ЧЬ** *сов.*— төеп ваклап бетерү.

**ИСТОЛО'ЧЬСЯ** *сов.* — төелеп ваклаңып бетү.

**ИСТО'МА** *ж. книж.* — изрәү, ою (наз-лаучан, рәхәт хәлсезләнү).

**ИСТОМИ'ТЬ** *сов.*— хәлдән тайдыру, хәлдән тайдырып бетерү, зарыктырып бетерү.

**ИСТОМИ'ТЬСЯ** *сов.* — ару, арып бетү, хәлдән таю, зарыгып бетү.

**ИСТОМЛЯ'ТЬ** *несов.*— к. истомить.

**ИСТОМЛЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. истомиться; 2. *страд.* хәлдән тайдырылу.

**ИСТОНЧА'ТЬ** *сов. книж. устар.*— нечкәрү, нәзекләнү, юкару, нечкәреп бетү, юкарып бетү.

**ИСТОНЧИ'ТЬ** *сов. разг. обл.*— нечкәртү, нәзекләндерү, юкарту, нечкәртеп бетерү, юкартып бетерү.

**ИСТОНЧИ'ТЬСЯ** *сов. разг. обл.* — к. истончать.

**ИСТОПИ'ТЬ** *сов.*— 1. ягу, ягып җылыту (мичне); 2. *разг.* ягып бетерү, ягуга тотып бетерү; *истопить кубометр дров* — бер кубометр утын ягып бетерү, бер кубометр утынны ягуга тотып бетерү; 3. эретеп бетерү; *истопить весь воск* — бөтен балавызны эретеп бетерү.

**ИСТОПИ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. *(кончить топиться)* янып бетү; *печь давно истопилась* — мич күптән янып бетте; 2. *разг.* *(растопиться до конца)* эреп бетү; *свинец истопился весь* — кургашын бөтенләй эреп бетте.

**ИСТОПНИ'К** *м.*— мич ягучы.

**ИСТОПТА'ТЬ** *сов.* — 1. *(измять)* таптап изеп бетерү (үләнне); 2. *простореч.* *(испачкать)* таптап пычратып бетерү (идәнне); 3. *простореч.* *(износить)* күп киеп туздырып бетерү (аяк киемен).

**ИСТОПТА'ТЬСЯ** *сов.* — 1. *(измяться)* тапталып бетү (үлән турында); 2. *простореч.* *(испачкаться)* тапталып пычранып бетү (идән турында); 3. *простореч.* *(износиться)* күп киелеп тузу, тузып бетү (аяк киеме турында).

**ИСТОРГА'ТЬ** *несов. книж. ритор.* — 1. *(выбрасывать)* ыргыту, ыргытып ташлау, чыгарып ташлау; *вулкан исторгает лаву* — вулкан лава ыргыта; 2. *(исключать, изгонять)* куу, сөрү, куып чыгару; *преступников исторгают из общества* — җинаятьчеләрне җәмгыятьтән сөрәләр; 3. *(выдёргивать)* суырып алу, тартып алу, суырып чыгару; *исторгать оружие из ножен* — коралны кынысыннан суырып (тартып) алу; 4. *перен.* *(вырывать, отнимать, освобождать)* коткару; *исторгать из рабства* — коллыктан коткару.

**ИСТОРГА'ТЬСЯ** *несов. страд., книж.-ритор., устар.*— 1. *(выбрасываться)* ыргытылу, чыгарып ташлану; 2. куылу, сөрелү, куып чыгарылу (мәсәлән, җинаятьче); 3. суырып алыну, тартып алыну (мәсәлән, корал кынадан); 4. *перен.* коткарылу.

**ИСТО'РГНУТЬ** *сов.*— к. исторгать.

**ИСТОРИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *науч.* — тарихилык принцибы, тарихка бәйләп карау принцибы.

**ИСТО'РИЙКА** *ж. разг. фам.* — кечкенә вакыйга, маҗара; кызыклы хәбәр.

**ИСТО'РИК** *м.*— тарихчы (1. тарих укытучысы яки тарих фәннәре галиме; 2. тарих факультеты студенты).

**ИСТОРИО'ГРАФ** *м. книж.* — историограф (1. историография белгече; 2. *устар.* тарихчы).

**ИСТОРИОГРАФИ'ЧЕСКИЙ** *науч.* —историографик...; историография...-ы; *историографическое отделение* — историография бүлеге.

**ИСТОРИОГРА'ФИЯ** *ж. мн.* нет, *науч.* — историография (тарих белеме үсешен һәм тарихи чыганакларны өйрәнә торган фән).

**ИСТОРИ'ЧЕСКИЙ** — 1. тарих...-ы; *историческая наука* — тарих фәне; 2. тарихи; *исторические сведения* — тарихи мәгълүматлар; *исторический роман* — тарихи роман; *исторический материализм* — тарихи материализм; *историческая дата* — тарихи дата; *историческое решение партии* — партиянең тарихи карары.

**ИСТОРИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— тарихи дөреслек; *в этом историческом романе очень мало историчности* — бу тарихи романда тарихи дөреслек бик аз.

**ИСТОРИ'ЧНЫЙ** — тарихи дөрес, тарихи фактларга туры килә торган.

**ИСТО'РИЯ** *ж.*— 1. тарих; *событие это вошло в историю* — бу вакыйга тарихка керде; *законы истории* — тарихның законнары; *история литературы* — әдәбият тарихы; 2. *разг.* вакыйга, хәл; *попасть в неприятную историю* — күңелсез вакыйгага очрау, күңелсез хәлгә төшү. ◇ **Об этом история умалчивает** — 1) бу турыда тарихта искә алынмый; 2) *перен. разг. шутл.* бу турыда тарих дәшми, бу турыда сөйләмиләр. **На памяти истории** *устар.* — тарихка билгеле вакытларда, тарихка билгеле елларда. **Вечная история!** *разг. фам.*— һаман бер балык башы. **Вот так история с географией** *разг. фам.*— менә сиңа кирәк булса! шул гына җитмәгән иде!

**ИСТОСКОВА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — сагыну, сагынып-саргаеп бетү.

**ИСТОЧА'ТЬ** *несов. книж. устар.* — 1. үзеннән агызу, саркыту; *горные расселины источали целительную влагу* — тау ярыклары шифалы су саркыталар иде (тау ярыкларыннан шифалы су саркып тора иде); 2. *(распространять, выделять из себя)* аңкыту, тарату; *цветы источают благовоние* — чәчәкләр хуш ис тараталар; 3. *перен.* *(изливать что-н.)* яудыру, коендыру; *источать милости* — мәрхәмәтләр яудыру.

**ИСТОЧА'ТЬСЯ** *несов. книж.*— 1. *(литься, испускаться)* агу, сарку; 2. *(выделяться, распространяться)* таралу, аңку; 3. *страд.* агызылу, саркытылу; таратылу, аңкытылу.

**ИСТОЧИ'ТЬ** I *сов. спец.* — 1. кайрый-кайрый юкартып бетерү, кайрап юкартып бетерү, чарлап юкартып бетерү; *источить нож* — пычакны кайрый-кайрый юкартып бетерү; 2. тишкәләп бетерү; *жучок источил дерево* — коңгыз агачны тишкәләп бетергән.

**ИСТОЧИ'ТЬ** II *сов. книж. устар.* — к. источать.

**ИСТОЧИ'ТЬСЯ** *сов. спец.*— кайрала-кайрала юкарып бетү, кайрала-кайрала ашалып бетү, чарлана-чарлана юкарып бетү; *нож источился совсем* — пычак кайрала-кайрала бөтенләй юкарып беткән.

**ИСТО'ЧНИК** *м.* — 1. *(родник)* чишмә, кизләү; 2. *перен.* нигез, чыганак; *труд* —

*источник благосостояния* — хезмәт — мул тормышның нигезе; 3. төп нөсхә, төп чыганак; *работа написана по источникам* — хезмәт төп чыганаклар буенча язылган.

**ИСТО'ШНЫЙ** *разг.* — ачы, йөрәк әрнеткеч, имәнеч (тавыш турында); *кричать истошным голосом* — ачы (йөрәк әрнеткеч) тавыш белән кычкыру.

**ИСТОЩА'ТЬ** *несов. книж.* — к. истощить.

**ИСТОЩА'ТЬСЯ** *несов. книж.* — 1. к. истощиться; 2. *страд.* ябыктырылу, арыгайтылу, хәлдән тайдырылу.

**ИСТОЩЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — 1. ябыгу, арыгаю, йончу (азык җитмәүдән); 2. бетү, тотылып бетү; *истощение средств* — средстволарның тотылып бетүе; 3. *(о почве)* азыкка ярлылану.

**ИСТОЩИ'ТЬ** *сов. книж.* — 1. ябыктыру, арыгайту, йончыту, хәлдән тайдыру, көчне бетерү; *лихорадка крайне истощила его* — бизгәк аны чиктән тыш ябыктырды; 2. бетерү; *истощить чьё-н. терпенье* — кемнеңдә булса түземлеген бетерү.

**ИСТОЩИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. *разг. (изнуриться, ослабеть)* ябыгу, арыгаю, йончу, хәлдән таю; 2. бетү; тотылып бетү; *запасы истощились* — запаслар бетте; 3. *(о почве)* азыкка ярлылану. ◇ Терпение моё истощилось — сабырым калмады, сабырым тәкәнде, түземлегем бетте.

**ИСТРА'ТИТЬ** *сов.* — тотып бетерү; *истратить деньги* — акчаны тотып бетерү.

**ИСТРА'ТИТЬСЯ** *сов.* — 1. тотылып бетү; *деньги истратились очень быстро* — акча бик тиз тотылып бетте; 2. *разг.* күп акча тоту, расходлану; *за этот месяц я очень истратился* — бу айда мин бик расходландым.

**ИСТРА'ЧИВАТЬ** *несов. редко* — к. истратить.

**ИСТРА'ЧИВАТЬСЯ** *несов. редко* — 1. к. истратиться; 2. *страд.* тотып бетерелү.

**ИСТРЕБИ'ТЕЛЬ** *м.* — 1. кырып бетерүче, үтереп бетерүче; *истребитель крыс* — күселәрне үтереп бетерүче; 2. *воен.* истребитель (сугыш вакытында дошман корабльләрен батырыр өчен торпедалар белән коралланган тиз йөрешле судно яки дошман самолётларын кырыр өчен кулланыла торган тиз йөрешле самолёт).

**ИСТРЕБИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.* — 1. *(уничтожающий)* һәлак иткеч; һәлак итә торган; кыра торган; *истребительный огонь артиллерии* — артиллериянең һәлак иткеч уты; 2. *авиац.* истребительләр...-ы; *истребительный отряд* — истребительләр отряды.

**ИСТРЕБИ'ТЬ** *сов.* — кырып бетерү, үтереп бетерү, юк итү, бетерү; *истребить клопов* — кандалаларны бетерү.

**ИСТРЕБЛЯ'ТЬ** *несов* — к. истребить.

**ИСТРЕБЛЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. кырылып бетү, үлеп бетү; 2. *страд.* кырып бетерелү, үтереп бетерелү.

**ИСТРЕ'БОВАТЬ** *сов. книж. офиц.* — таләп итеп алу, сорап алу, соратып алдыру; *истребовать документы* — документларны таләп итеп алу (соратып алдыру).

**ИСТРЕПА'ТЬ** *сов.* — туздырып бетерү, таушалдырып бетерү, искертеп бетерү; *истрепать книгу* — китапны таушалдырып бетерү; *истрепать сапоги* — итекләрне туздырып бетерү. ◇ Истрепать нервы *разг. фам.* — нервларны бозып бетерү; нервларны эштән чыгару.

**ИСТРЕПА'ТЬСЯ** *сов.* — 1. тузып бетү, таушалып бетү, искереп бетү; *книга истрепалась* — китап таушалып беткән; *пальто истрепалось* — пальто тузып беткән; 2. *вульг.* сәламәтлекне югалту.

**ИСТРЁПЫВАТЬ** *несов. разг.* — к. истрепать.

**ИСТРЁПЫВАТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. к. истрепаться; 2. *страд.* туздырып бетерелү, таушалдырып бетерелү.

**ИСТРЕ'СКАТЬСЯ** *сов. разг.* — чатнап ярылып бетү, яргаланып бетү; *лёд весь истрескался* — боз бөтенләй чатнап ярылып беткән, боз яргаланып беткән.

**ИСТРУХЛЯ'ВЕТЬ** *сов. простореч.* — вакланып бетү, тузанга әверелеп бетү (мәсәлән, черегән агач төбе).

**ИСТРУХЛЯ'ВИТЬ** *сов. простореч.* — ваклап бетерү (мәсәлән, үтә коры печәнне).

**ИСТРУХЛЯ'ВИТЬСЯ** *сов. простореч.* — к. иструхляветь.

**ИСТУКА'Н** *м. устар.* — 1. *(идол)* санам, сын, пот; 2. *пренебр. шутл.* начар ясалган сын. ◇ Стоять истуканом или как истукан *разг.* — тораташ кебек катып басып тору.

**ИСТУПИ'ТЬ** *сов.* — үтмәсләндереп бетерү.

**ИСТУПИ'ТЬСЯ** *сов.* — үтмәсләнеп бетү.

**ИСТУПЛЯ'ТЬ** *несов. простореч.* — к. иступить.

**ИСТУПЛЯ'ТЬСЯ** *несов. простореч.* — 1. к. иступиться; 2. *страд.* үтмәсләндереп бетерелү.

**И'СТЫЙ** *книж.* — чын, бирелеп эшли торган, ихлас белән эшли торган; *истый охотник* — чын сунарчы, чын аучы.

**ИСТЫ'КАТЬ** *сов. разг.* — чәнечкәләп бетерү, чәнчеп тишкәләп бетерү, кадап тишкәләп бетерү; *истыкать иголкой* — инә белән чәнечкәләп бетерү.

**ИСТЫ'КАТЬСЯ** *сов. разг.* — чәнечкәләнеп бетү, чәнчелеп тишкәләнеп бетү, кадалып тишкәләнеп бетү.

**ИСТЫ'КИВАТЬ** *несов. разг.* — к. истыкать.

**ИСТЫ'КИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. к. истыкаться; 2. *страд.* — чәнечкәләп бетерелү, чәнчеп тишкәләп бетерелү.

**ИСТЯЗА'ТЕЛЬ** *м.* — газаплаучы, интектерүче, җәфалаучы.

**ИСТЯЗА'ТЬ** *несов. книж.* — (аяусыз) газаплау, интектерү, җәфалау; *истязать себя страшными думами* — үзеңне куркыныч уйлар белән газаплау.

**ИСТЯЗА'ТЬСЯ** *несов. страд. книж.* — интектерелү.

**ИСХА'ЖИВАТЬ** *многокр. разг.* — күп җирләрне йөреп чыгу, күп урында булу.

**ИСХАМИ'ТЬСЯ** *сов. простореч. вульг.*— оятсызланып бетү, тупасланып бетү.

**ИСХАРЧИ'ТЬСЯ** *сов. простореч.*— ашауга тотып бетерү, ашауга күп акча тоту.

**ИСХА'ЯТЬ** *сов. простореч.*— хурлап бетерү, хурлап юкка чыгару; *исхаял купленное товарищем пальто* — иптәше сатып алган пальтоны хурлап бетерде.

**ИСХИТРИ'ТЬСЯ** *несов. разг.* — хәйләсен табу.

**ИСХИТРЯ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— к. исхитриться.

**ИСХЛЕСТА'ТЬ** *сов. простореч.*— 1. *(избить, хлеща чем-н.)* камчылау, суктыру; 2. *(испортить хлестаньем)* камчылый-камчылый туздырып бетерү (камчы, чыбыркы турында).

**ИСХЛЕСТА'ТЬСЯ** *сов. простореч.*— күп камчылаудан тузып бетү (камчы, чыбыркы турында).

**ИСХЛЁСТЫВАТЬ** *несов. простореч.* — к. исхлестать.

**ИСХЛЁСТЫВАТЬСЯ** *несов. простореч.*— 1. к. исхлестаться; 2. *страд.* суктырылу.

**ИСХЛОПОТА'ТЬ** *сов. разг.*— юллап алу, артыннан йөреп алу; *исхлопотать себе внеочередной отпуск* — үзенә чираттан тыш ял юллап алу.

**ИСХЛОПОТА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — мәшәкатьләнеп арып бетү, артыннан йөреп арып бетү.

**ИСХО'Д** *м. книж.*— 1. *устар. (выход, движение)* чыгып китү; 2. *(окончание, результат)* бетү, ахыр, нәтиҗә; *исход дела* — эшнең бетүе (ахыры, нәтиҗәсе). ◇ В исходе — азагына таба, ахырына таба; *в исходе дня* — көн ахырына таба. Быть на исходе *книж.*— бетеп килү, бетүгә якынаеп килү; *патроны были на исходе* — патроннар бетеп килә иде.

**ИСХОДА'ТАЙСТВОВАТЬ** *сов. офиц. канц.*— юллап алу, артыннан йөреп алу; *исходатайствовать пенсию* — пенсия юллап алу.

**ИСХОДИ'ТЬ** I *сов.* — җәяү йөреп чыгу (җәяү йөреп күп җирләрдә булу); *исходить весь край* — бөтен крайны җәяү йөреп чыгу.

**ИСХОДИ'ТЬ** II *несов.* — 1. *книж.* чыгу, алыну; *сведения исходят из достоверного источника* — мәгълүматлар ышанычлы чыганактан алынган (чыккан); 2. *книж.* алу, ...чыгып эш итү, чыгу, эш итү; *исходить из учёта всех обстоятельств* — бөтен хәлләрне исәпкә алып эш итү; 3. *разг. (ослабевать)* йөдәү, әлсерәү, хәлсезләнү (елап, яки кан югалтып).

**ИСХО'ДНЫЙ** *книж.* — башлангыч, элекке, баштагы; *вернуться к исходному положению* — элекке хәленә кайту.

**ИСХОДЯ'** *нареч.*— чыгып, күздә тотып.

**ИСХОДЯ'ЩАЯ** *в знач. сущ.* — җибәрелә торган документ (кәгазь).

**ИСХОДЯ'ЩИЙ** — чыга торган, тарала торган. ◇ **Исходящий журнал** — җибәрелә торган документларны (кәгазьләрне) язу журналы. **Исходящий номер** — җибәрелә торган документның (кәгазьнең) номеры.

**ИСХУДА'ЛЫЙ** — бик ябык, бик арык, ябыккан, арыгайган; *исхудалое лицо* — бик ябык йөз.

**ИСХУДА'ТЬ** *сов.*— бик ябыгу, бик арыклану.

**ИСЦАРА'ПАТЬ** *сов.*— тырнап бетерү.

**ИСЦАРА'ПАТЬСЯ** *сов. разг.*— тырналып бетү.

**ИСЦАРА'ПЫВАТЬ** *несов.* — к. исцарапать.

**ИСЦАРА'ПЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. исцарапаться; 2. *страд.* тырнап бетерелү.

**ИСЦЕЛЕ'НИЕ** *ср. книж.* — савыктыру, сәламәтләндерү, терелтү; савыгу, сәламәтләнү, терелү.

**ИСЦЕЛИ'ТЕЛЬ** *м. книж.* — савыктыручы сәламәтләндерүче, терелтүче.

**ИСЦЕЛИ'ТЬ** *сов. книж.* — савыктыру, терелтү, сәламәтләндерү.

**ИСЦЕЛИ'ТЬСЯ** *сов. книж.*— савыгу, терелү, сәламәтләнү.

**ИСЦЕЛЯ'ТЬ** *несов. книж.*— к. исцелить.

**ИСЦЕЛЯ'ТЬСЯ** *несов. книж.* — 1. к. исцелиться; 2. *страд.* савыктырылу, сәламәтләндерелү.

**ИСЧА'ДИЕ** *ср. книж. ритор.:* **исчадие сатаны** — иблис токымы; **исчадие ада** — тәмуг кисәве.

**ИСЧА'ХНУТЬ** *сов.* — ябыгу, кору, кибү; *исчахнуть от болезни* — авырудан ябыгу, авырудан кибү.

**ИСЧЕЗА'ТЬ** *несов.*— к. исчезнуть.

**ИСЧЕЗНОВЕ'НИЕ** *ср. книж.*— югалу, юк булу, юкка чыгу.

**ИСЧЕ'ЗНУТЬ** *сов.* — 1. бетү, юк булу; юкка чыгу; *к утру туман исчез* — иртәнгә таба томан бетте (юкка чыкты); 2. югалу; *карандаш исчез* — карандаш югалды.

**ИСЧЁРКАТЬ** и **ИСЧЕРКА'ТЬ** *сов. разг.*— сызгалап бетерү (кәгазьне).

**ИСЧЕ'РПАТЬ** *сов. книж.* — 1. *(истратить)* тотып бетерү; 2. бетерү, карап бетерү, тәмамлау; *исчерпать повестку заседания* — утырышның көн тәртибен карап бетерү.

**ИСЧЕ'РПЫВАТЬ** *несов. книж.* — к. исчерпать.

**ИСЧЕ'РПЫВАТЬСЯ** *несов. книж.*— бетү, тәмам булу, тәмамлану.

**ИСЧЕ'РПЫВАЮЩЕ** *нареч.* — тулысынча, бөтен тулылыгы белән; *исчерпывающе изложить факты* — фактларны бөтен тулылыгы белән сөйләп бирү.

**ИСЧЕ'РПЫВАЮЩИЙ** *книж.*— тулы; *исчерпывающий ответ* — тулы җавап.

**ИСЧЕРТИ'ТЬ** *сов.*— 1. сызгалап бетерү, сызыклар белән тутыру; 2. сыза-сыза тотып бетерү; *исчертить весь мел* — бөтен акбурны сыза-сыза тотып бетерү.

**ИСЧЕРТИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. сызгаланып бетү; 2. сыза-сыза тотылып бетү (мәсәлән, карандаш, акбур).

**ИСЧЕ'РЧИВАТЬ** *несов.*— к. исчертить.

**ИСЧЕ'РЧИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. исчертиться; 2. *страд.* сызгалап бетерелү.

**ИСЧИ'РКАТЬ** *сов. разг.* — яндырып бетерү (барлык шырпыны).

**ИСЧИ'СЛИТЬ** *сов. книж.*— исәпләү, исәп-

әәп чыгару; *исчислить стоимость ремонта* — ремонтның күпмегә төшәчәген исәпләп чыгару.

**ИСЧИСЛЯ'ТЬ** *несов. книж.* — к. исчислить.

**ИСЧИСЛЯ'ТЬСЯ** *несов. книж.* — 1. исәпләнү; *потери в боях исчисляются тысячами* — сугышта югалтулар меңнәр белән исәпләнә; 2. *страд.* исәпләп чыгарылу.

**ИСША'РИТЬ** *сов. разг.* — актарып чыгу; *исшарил всё в шкафу и не нашёл* — шкафтагы бөтен әйберләрне актарып чыктым, ләкин тапмадым.

**ИСША'РКАТЬ** *сов. простореч.* — йөри-йөри шомартып бетерү.

**ИСШНЫ'РИТЬ** *сов. простореч.* — әрле-бирле сугылып йөреп чыгу; *исшнырить все углы в доме* — әрле-бирле сугылып өйдәге барлык почмакларны йөреп чыгу.

**ИСЩИПА'ТЬ** *сов. простореч. разг.* — чеметкәләп бетерү.

**ИТА'К** *союз* — шулай, димәк, шулай итеп, шулай булгач; *итак, вопрос решён* — шулай итеп, мәсьәлә хәл ителде.

**ИТАЛЬЯ'НЕЦ** *м.* — италияле, Италия кешесе.

**ИТАЛЬЯ'НКА** *ж.* — 1. к. итальянец; 2. тальян гармонь; *взял гармонью-итальянку и с радости заиграл* — тальян гармонен алды да, шатлыгыннан уйнап җибәрде.

**ИТАЛЬЯ'НСКИЙ** — итальян...-ы; *итальянский язык* — итальян теле.

**ИТАЛЬЯ'НЦЫ** *мн.* — итальяннар, италиялеләр, Италия халкы.

**ИТЕРАТИ'ВНЫЙ** *лингв.* — кабатлаулы; *итеративные глаголы* — кабатлаулы фигыльләр.

**ИТО'Г** *м.* — 1. *бухг.* гомуми сумма, итог; 2. *перен. (результат)* нәтиҗә, йомгак; *подводить итоги* — нәтиҗә ясау, йомгаклау.

**ИТОГО'** *нареч. бухг. канц.* — барлыгы, бөтенесе.

**ИТО'ГОВЫЙ** *бухг. канц.* — итог...-ы; *итоговая сумма* — итог суммасы.

**ИТО'ЖИТЬ** *несов. бухг. канц.* — йомгаклау, итоглау.

**ИТТИ'** — к. идти.

**ИТТИ'СЬ** (или иатись) *несов. безл. разг.* — барылу; *сегодня идётся хорошо* — бүген яхшы барыла. ◇ **Мне идётся легко** — мин җиңел барам. **Мне не идётся** — барып булмый; барасым килми.

**ИУ'ДА** *м. бран.* — хыянәтче, сатлык.

**ИХТИОЗА'ВР** *м. палеонт.* — ихтиозавр (казылма хәлендә табыла торган зур диңгез хайваны).

**ИХТИО'Л** *м. мн.* нет, *мед. апт.* — ихтиол (кайбер тире авыруларын һ. б. дәвалый торган майсыман дару).

**ИХТИО'ЛОГ** *м.* — ихтиолог (ихтиология галиме).

**ИХТИОЛОГИ'ЧЕСКИЙ** — ихтиология...-ы; *ихтиологический отдел музея* — музейның ихтиология бүлеге.

**ИХТИОЛО'ГИЯ** *ж. мн.* нет — ихтиология (балыкларны өйрәнү фәне).

**ИША'К** *м. обл.* — 1. ишәк; 2. *перен. бран.* аңгыра, юләр, мәнсез, акылсыз, ишәк.

**И'ШИАС** *м. мн.* нет — ишиас (нерв авыруы).

**ИШЬ** *межд. простореч.* — кара, кара син аны, әнә; *ишь, как быстро идёт!* — кара син аны, ничек тиз бара!

**ИШЬ-ТЫ** *простореч.* — 1. кара син аны; 2. тот капчыгыңны; *ишь-ты, так я тебе и дал!* — тот капчыгыңны, бирәм ди мин сиңа!

**ИЩЕ'ЙКА** *ж.* — 1. ищейка (качкан җинаятьчеләрне яки урланган әйберне эзләү өчен өйрәтелә торган эт токымы); 2. *перен. презрит.* шымчы.

**ИЮ'ЛЬ** *м. мн.* нет — июль.

**ИЮ'ЛЬСКИЙ** — июль...-ы; *июльские дни* — июль көннәре.

**ИЮ'НЬ** *м. мн.* нет — июнь.

**ИЮ'НЬСКИЙ** — июнь...-ы; *июньское восстание* — июнь восстаниесе (Парижда 1848 елгы восстание).

# К

**К** (ко) *предлог с дат. п.* — 1...-га,...-гә таба,... янына; *ученик вышел к доске* — укучы тактага (такта янына) чыкты; *охотники направились к лесу* — аучылар урманга таба юнәлделәр; 2. ...-га, ...-гә таба; *к завтрашнему дню эту работу надо кончить* — иртәге көнгә бу эшне тәмамларга кирәк; *к вечеру пошёл дождь* — кичкә таба яңгыр ява башлады; *подготовиться к экзамену* — экзаменга хәзерләнү; *любовь к Родине* — Ватанга мәхәббәт; *принять к сведению* — исәпкә алырга; *к завтрашнему заседанию* — иртәгәге утырышка; *к трём прибавить два* — өчкә икене кушарга; 3. ...-га карата; *к вопросу о происхождении языка* — телнең килеп чыгышы мәсьәләсенә карата. ◇ **Это тебе не к лицу** — бу эш сиңа ярамый, бу эш сиңа килешми. **К счастью** — бәхеткә каршы. **К сожалению** — үкенечкә каршы, кызганычка каршы. **К тому же** — шуның өстенә. **К слову сказать** — сүз арасында әйткәндә, сүз арасында әйтергә кирәк. **Не ко времени** — вакыты түгел, вакытсыз.

**-КА** *частица простореч.* — әле, ...-чы, ...-сәнә; *дайте-ка пройти* — ягез, үтеп китим әле, үтеп китәргә рөхсәт итегезче; *заеду-ка я в самом деле к Ноздрёву* (Гоголь) — чыннан да мин Ноздрёвка кереп чыгыйм әле.

**КАБА'К I** *м.* — 1. *истор.* кабак (исерткечләр сату урыны); 2. *перен. разг. фам.*

тәртипсезлек, шапшаклык, шау-шу; *на улицах кабак, нечистота* (Гоголь) — урамнарда тәртипсезлек, пычраклык; урамнарда кабактагы шикелле шау-шу, пычраклык.

**КАБА'К** II *м. обл. бот.* — к. кабачок II.

**КАБАЛА'** *ж.* — 1. кабала, коллык (Мсква Русенда — махсус договорга нигезләнгән гомерлек коллык); 2. коллык, тулы бәйлелек; *народы колониальных стран восстали против империалистической кабалы* — колониаль илләрнең халыклары империалистик коллыкка каршы күтәрелделәр; 3. *перен. книж.* рухи коллык, колларча бәйлелек.

**КАБАЛИ'СТИКА** *ж. мн.* нет — к. каббалистика.

**КАБАЛИСТИ'ЧЕСКИЙ** — к. каббалистический.

**КАБАЛИ'ТЬ** *несов.* — кабалага кертү, коллыкка төшерү.

**КАБА'ЛЬНЫЙ** — 1. *истор.* кабала...-ы; *кабальная запись* — кабала язмасы; 2. кабалалы; *кабальный договор* — кабалалы договор; 3. *разг. (зависимый, несвободный)* кабаладагы, бәйле.

**КАБА'Н** *м.* — 1. *(дикая свинья)* кабан дуңгызы; 2. *(самец домашней свиньи)* ата дуңгыз; 3. *перен. бран. простореч. (о грубом, грузном мужчине)* зур гәүдәле тупас ир кеше, дуңгыз, кабан дуңгызы; 4. *спец.* зур кисәк; *кабан руды* — зур руда кисәге.

**КАБА'НИЙ** — кабан дуңгызы...-ы, кабан дуңгызлары...-ы; *кабанье копыто* — кабан дуңгызы тоягы; *кабанье стадо* — кабан дуңгызлары көтүе.

**КАБАНИ'НА** *ж. мн.* нет, *обл.* — кабан дуңгызы ите.

**КАБАРГА'** *ж. зоол.* — кабарга (Себердә боланнар семьялыгыннан булган хайван).

**КАБАРДИ'НКА** *ж.* — кабардинка (1. кабарда халкының хатын-кызы; 2. бию исеме; 3. тукыманың бер төре).

**КАБАРДИ'НСКИЙ** — кабарда...-ы; *кабардинский язык* — кабарда теле.

**КАБАРДИ'НЦЫ** *мн.* (*ед.* кабардинец) — кабардалылар, кабарда халкы (Кавказда яшәүче халыкларның берсе).

**КАБАРЕ'** *ср. нескл.* — кабаре (буржуаз илләрдә эстрадалы кафе яки ресторан).

**КАБА'ТЧИК** *м.*, **КАБА'ТЧИЦА** *ж. дореvол.* — кабакчы, кабак тотучы.

**КАБА'ЦКИЙ** — 1. кабак...-ы; *кабацкое вино* — кабак аракысы; 2. *перен. разг. неодобр.* әдәпсез, тупас, кабак...-ы; *кабацкие нравы* — тупас гадәтләр, кабак гадәтләре.

**КАБАЧО'К** I *дореvол.* — 1. кечкенә кабак; 2. *разг. фам.* кечкенә ресторан.

**КАБАЧО'К** II *бот.* — ташкабак (яшелчә).

**КАББАЛА'** *ж. мн.* нет — 1. *истор.* каббала (урта гасырларда еврейләрдә һәртөрле хорафат һәм мистикага корылган дини тәгълимат); 2. *книж. редко перен.* аңлаешсыз нәрсә, буталчык нәрсә, фән белән бәйләнешсез нәрсә (берәр текст, язылган әйбер турында).

**КАББАЛИ'СТИКА** *ж. мн.* нет — 1. *книж. истор.* каббалистика (каббала белән бәйләнгән йолалар); 2. *перен. ирон.* аңлаешсыз буталчык, серле нәрсә; 3. *разг.* к. каббала 2.

**КАББАЛИСТИ'ЧЕСКИЙ** — 1. каббалистик, аңлаешсыз, буталчык; *каббалистический текст* — каббалистик текст, аңлаешсыз (буталчык) текст; 2. *перен.* серле; *каббалистические знаки* — серле билгеләр (тамгалар).

**КА'БЕЛЬ** *м.* — кабель (1. *тех.* бер-берсеннән изоляцияләнеп, саклагыч тышча белән капланган берничә яки бер үткәргеч. Гадәттә, җир һәм су астыннан электр энергиясен үткәрү өчен кулланыла; 2. *мор.* тимер яки корыч чыбыклардан ишелгән канат).

**КА'БЕЛЬНЫЙ** *тех.* — 1. кабельле; *кабельная линия* — кабельле линия; 2. кабель...-ы; *кабельный завод* — кабель заводы.

**КА'БЕЛЬТОВ** *м. мор.* — кабельтов (1. флотта 185,2 метр озынлыгындагы үлчәү берәмлеге; *со скоростью восьми кабельтов в час* — сәгатькә сигез кабельтов тизлек белән; 2. шул озынлыктагы кабель).

**КА'БЕЛЬТОВЫЙ** *мор.* — бер кабельтовлы, бер кабельтов озынлыгындагы.

[**КА'БЕЛЬТОВЫЙ**]: *пятикабельтовый* — биш кабельтовлы.

**КА'БЕЛЬЩИК** *м. спец.* — кабельщик (кабель ясау яки кабель сузу белән шөгыльләнүче эшче).

**КАБЕСТА'Н** *м. тех.* — кабестан (йөкне бер урыннан икенче урынга күчерү өчен кулланыла торган механизм).

**КАБИ'НА** *ж.* — кабина (билгеле бер максат өчен махсус җиһазландырылган кечкенә генә бүлмә, будка); *кабина для переговоров по телефону* — телефоннан сөйләшү кабинасы; *кабина шофёра* — шофёр кабинасы.

**КАБИНЕ'Т** *м.* — 1. кабинет (эш бүлмәсе); *кабинет директора* — директор кабинеты; *зубоврачебный кабинет* — теш дәвалау кабинеты; *физический кабинет* — физика кабинеты; 2. *разг.* бер комплект кабинет мебеле; *купить кабинет красного дерева* — кызыл агачтан ясалган бер комплект кабинет мебеле сатып алу; 5. *собир. полит. загр.* кабинет, хөкүмәт (кайбер илләрдә хөкүмәт тәшкил итә торган министрлар составы); *кабинет министров* — министрлар кабинеты (хөкүмәт).

**КАБИНЕ'ТНОСТЬ** *ж. мн.* нет — практикадан ерәклык, практикага нигезләнмәгәнлек.

**КАБИНЕ'ТНЫЙ** — 1. кабинет...-ы; *кабинетная мебель* — кабинет мебеле; 2. *перен. книж.* практикадан ерак, практикага нигезләнмәгән; *кабинетные проекты* — практикага нигезләнмәгән проектлар.

**КАБИНЕ'ТСКИЙ** *книж.* — хөкүмәт...-ы; *кабинетский кризис* — хөкүмәт кризисы.

**КАБИ'НКА** *ж.* — к. кабина.

**КАБЛОГРА'ММА** *ж. спец.* — каблограмма (кабель буенча бирелгән телеграмма).

**КАБЛУ'К** *м.* — үкчә (аяк киемендә).

**КАБЛУ'ЧНЫЙ** — үкчә...-ы; *каблучный гвоздь* — үкчә кадагы.

**КАБЛУЧО'К** *м.* — 1. к. каблук; 2. *архит.* каблучок (кәрниз кисәкләренең берсе).

**КАБОТА'Ж** *м. мн.* нет, *мор.* — каботаж (1. диңгез буе пароходчылыгы; 2. диңгез яры буенда гына йөри торган флот).

**КАБОТА'ЖНИК** *м. мор.* — каботажник (1. каботаж флотта хезмәт итүче диңгезче; 2. *разг.* диңгез яры буенда гына йөри торган судно).

**КАБОТА'ЖНИЧАТЬ** *несов. мор.* — каботаж белән шөгыльләнү.

**КАБОТА'ЖНЫЙ** *мор.* — каботаж...-ы; *каботажный флот* — каботаж флоты.

**КАБРИОЛЕ'Т** *м.* — кабриолет (ике көпчәкле, бер генә утыргычлы җиңел арба).

**КАБРИОЛЕ'ТКА** *ж. разг. устар.* — к. кабриолет.

**КАБЫ'** *союз. разг. просторeч.* — әгәр, әгәр дә; *кабы я знал, не пошёл бы* — әгәр дә белсәм, бармаган булыр идем.

**КАВАЛЕ'Р** I *м.* — кавалер (орден белән бүләкләнгән кеше; *кавалер ордена Отечественной войны* — Ватан сугышы ордены кавалеры, Ватан сугышы ордены белән бүләкләнгән кеше). ◇ **Георгиевский кавалер** — Георгиевский кавалер (революциягә кадәр: батырлык күрсәткән өчен Георгиевский крест белән бүләкләнгән гаскәри).

**КАВАЛЕ'Р** II *м.* — кавалер (1. парлы танецта хатын-кыз белән биюче ир кеше; 2. *устар.* буржуаз-дворяннар средасында кунак мәҗлесендә хатын-кызга аеруча илтифат күрсәтеп, аның кәефен табарга тырышучы ир кеше; 3. *просторeч.* хатын-кыз артыннан йөрүче, аның сөйгән егете яки сеяркәсе; 4. *дореволюц.* и *загр.* берәр орденның (җәмгыятьнең) члены булып, шул орденга (җәмгыятькә) хас берәр төрле знакка ия булган кеше).

**КАВАЛЕРГА'РД** *м. воен. дореволюц.* — кавалергард (патша армиясендә атлы гвардия полкында хезмәт итүче солдат яки офицер).

**КАВАЛЕРГА'РДСКИЙ** *воен. дореволюц.* — кавалергард...-ы, кавалергардлар...-ы; *кавалергардский мундир* — кавалергард мундиры; *кавалергардский полк* — кавалергардлар полкы.

**КАВАЛЕРИ'ЙСКИЙ** *воен.* — 1. кавалерия...-ы; *кавалерийский полк* — кавалерия полкы; 2. *разг.* кавалеристларча; *кавалерийская походка* — кавалеристларча йөреш.

**КАВАЛЕРИ'СТ** *м.* — кавалерист (1. атлы гаскәрдә хезмәт итүче; 2. *разг.* атта оста йөрүче).

**КАВАЛЕ'РИЯ** *ж. воен.* — кавалерия, атлы гаскәр.

**КАВАЛЕ'РСКИЙ** *устар.* — кавалерлык...-ы; *кавалерские ухватки* — кавалерлык кыланышлары.

**КАВАЛЬКА'ДА** *ж.* — кавалькада, атлылар группасы, җайдаклар төркеме.

**КАВАРДА'К** *м. разг. фам.* — тәртипсезлек, чуалчыклык, буталчыклык, ыгы-зыгы.

**КА'ВЕРЗА** *ж. разг.* — 1. *устар.* бутау, буталчыклык тудыру (эштә); 2. интрига, мәкер, усал ният белән эшләнгән хәйлә.

**КА'ВЕРЗИТЬ** *несов. просторeч.* — 1. буталчыклык тудыру (эштә); 2. усаллык итү, явызлык итү.

**КА'ВЕРЗНИК** *м.*, **КА'ВЕРЗНИЦА** *ж. просторeч.* — 1. усаллык итүче, явызлык итүче; мәкерле, хәйләле кеше; 2. буталчыклар тудыручы.

**КА'ВЕРЗНИЧАТЬ** *несов. просторeч.* — к. каверзить.

**КА'ВЕРЗНОСТЬ** *ж. мн.* нет — мәкерлелек, хәйләлелек.

**КА'ВЕРЗНЫЙ** *просторeч.* — 1. буталчык, четерекле, кыен чишелешле; *каверзное дело* — буталчык эш; 2. мәкерле; *каверзные люди* — мәкерле кешеләр.

**КАВЕ'РНА** *ж. мед.* — каверна (органик тканьның үле өлешендәге куышлык, бушлык).

**КАВКА'ЗЕЦ** *м.* — кавказлы, кавказ кешесе.

**КАВКА'ЗКА** *ж.* — кавказлы хатын-кыз.

**КАВКА'ЗСКИЙ** — Кавказ...-ы; *кавказские горы* — Кавказ таулары.

**КАВЫ'ЧКИ** *ед.* нет — куш җәяләр, куш тырнаклар („ " яки « » рәвешендә язуда куела торган билге).

**КАГА'Л** *м.* — 1. *истор.* кагал (элекке Польшада суд һәм административ орган буларак еврей старшиналарының җыелышы); 2. *перен. просторeч.* шау-шулы төркем, тәртипсез төркем, шау-шулы халык төркеме.

**КАГО'Р** *м. мн.* нет — кагор (кызыл аракының бер төре).

**КАГУА'Р** *м. зоол.* — к. кугуар.

**КАДА'СТР** *м. спец.* — кадастр (налог салынырга тиешле объектлар исемлеге).

**КАДЕ'Т** I *м. дореволюц.* — кадет, кадетский корпуста укучы.

**КАДЕ'Т** II *м. истор. полит.* — кадет (революциягә чаклы Россиядә конституцион-демократик партия дип аталган буржуаз контрреволюцион партиянең члены).

**КАДЕТСКИЙ** I *дореволюц.* — кадетский; *кадетский корпус* — кадетский корпус (революциягә кадәр Россиядә дворян һәм офицер балаларын офицерлык хезмәтенә хәзерли торган гаскәри урта уку йорты).

**КАДЕ'ТСКИЙ** II *полит.* — кадетлар...-ы; *кадетская партия* — кадетлар партиясе.

**КА'ДИ** *нескл.*, **КА'ДИЙ** *м.* — казый (мөселманнарда судья).

**КАДИ'ЛО** *ср. церк.* — кадило (чиркәүдә ладан яндырып төтәсли торган металл савыт).

**КАДИ'ЛЬНЫЙ** *церк.* — кадило...-ы; *кадильный дым* — кадило төтене.

**КАДИ'ТЬ** *несов.* — 1. *церк.* ладан төтене белән төтәсләү; 2. *перен. разг. неодобр.* ялагайлану, тәлинкә тоту.

**КА'ДКА** *ж.* — кисмәк.

**КА'ДМИЙ** *м. мн.* нет — кадмий (1. *хим.* ялтыравыклы йомшак ак металл; 2. шул металлдан ясалган сары буяу).

**КА'ДОЧНИК** *м. спец.* — кисмәкче, кисмәк остасы.

**КА'ДОЧНЫЙ** — кисмәк...-ы; *кадочный обруч* — кисмәк кыршавы.

**КАДР** *м. кино* — кадр (киноплёнкада аерым снимок, сцена).

**КАДРИ'ЛЬ** *ж. истор.* — кадриль (1. алты кешелек танец; 2. шул танецның музыкасы).

**КАДРОВИ'К** *м.* — кадровик (1. *воен.* кадровый частьларда хезмәт итүче гаскәри; 2. *спец.* кадровый работник).

**КА'ДРОВЫЙ** — кадровый, кадрда торучы.

**КА'ДРЫ** *мн.* — 1. *воен.* кадр (хәрби частьларның тыныч вакыттагы даими составы); 2. кадрлар (берәр эштә, производствода эшләүче работниклар составы); *борьба за кадры* — кадрлар өчен көрәш.

**КАДУ'ШЕЧНЫЙ** *разг.* — кисмәк...-ы; *кадушечное производство* — кисмәк производствосы.

**КАДУ'ШКА** *ж.* — к. кадка.

**КАДЫ'К** *м. разг.* — бугаз төене, чалу сөяге.

**КАЁМКА** *ж. разг.* — тар кайма.

**КАЁМОЧНЫЙ** *разг.* — кайма...-ы; каймалык...; *каёмочный материал* — каймалык материал.

**КАЁМЧАТЫЙ** — каймалы, кайма тоткан; *каёмчатый платок* — каймалы яулык.

**КАЖДОГО'ДНИЙ, КАЖДОГО'ДНЫЙ** *книж. устар.* — һәр елгы, ел саен була торган.

**КАЖДОДНЕ'ВНЫЙ** *книж.* — һәр көнге, көн дә була торган, көн саен була торган.

**КА'ЖДЫЙ** — 1. һәр, саен, һәрберсе, һәркайсы; *каждый человек* — һәр кеше; *каждый день* — һәр көн, көн саен; *каждый из учеников получил по книге* — укучыларның һәрберсе (һәркайсы) берәр китап алды; 2. *в знач. сущ.* һәркем; *пусть каждый заботится сам о себе* — һәркем үзе турында үзе кайгыртсын.

**КА'ЖЕТСЯ** *ввод. сл.* — бугай, ахры, ахрысы, булса кирәк; *вы, кажется, из Москвы?* — сез Москвадан бугай?

**КАЖИ'ННЫЙ** *обл.* — һәр; *кажинный раз на этом месте* — һәрвакыт шушы урында.

**КАЖИ'СЬ** *ввод. сл. простореч. обл.* — к. кажется.

**КА'ЖНЫЙ** *обл.* — к. каждый.

**КАЗА'К** *м.* — казак (1. *истор.* Москва Русенда һәм борынгы заманда Украинада: дәүләтнең чик өлкәләренә күчеп барып урнашып дәүләт чикләрен саклауда һәм киңәйтүдә актив катнашкан хәрби-игенчелек общинасы члены; *запорожский казак* — Запорожье казагы; 2. Дон, Урал, Терек елгалары буенда һәм кайбер башка өлкәләрдә шул килүчеләр нәселеннән булган крестьян; шул крестьяннардан оештырылган хәрби частьның солдаты). ◇ **Вольный казак** *разг.*—тәмам азат кеше, бәйсез кеше.

**КАЗАКИ'Н** *м. устар.* — кәзәки (кием).

**КАЗА'ЛОСЬ** *ввод. сл.* — кебек; *казалось, всё было хорошо* — барысы да яхшы кебек иде.

**КАЗА'Н** *м.* — 1. *обл.* зур казан. 2. *спец.* казан.

**КАЗАРМА** *ж.* — казарма (1. гаскәри часть яши торган бина; 2. *дореволюц.* фабрикалар карамагында эшчеләр тулай торагы; 3. *перен. разг. пренебр.* ямьсез, шыксыз бина).

**КАЗА'РМЕННЫЙ** — 1. казармада...; *казарменное учение* — казармада өйрәтү; 2. казарма...-ы; *казарменные порядки* — казарма тәртипләре; 3. *перен. пренебр. устар.* тупас, дорфа; *казарменная шутка* — тупас шаяру.

**КАЗА'ТЬ** *несов. простореч.* — күрсәтү. ◇ **Не казать глаз, носу** *разг.* — күренмәү, эзе дә булмау; *выбрось вон этого негодяя, и чтоб он не смел глаз казать сюда* — куып чыгар шул явызны, моннан соң аның бередә эзе дә булмасын.

**КАЗА'ТЬСЯ** *несов.* — күренү, булып күренү; *казаться старше своих лет* — үзенең яшенә караганда картрак булып күрену. ◇ **Мне кажется** (**нам кажется** и т. п.) — минемчә, минем уемча (безнеңчә, безнең уебызча һ. б.).

**КАЗА'ХИ** *мн.* (*ед.* казах) — казахлар, казах халкы.

**КАЗА'ХСКИЙ** — казах...-ы; *казахский язык* — казах теле.

**КАЗА'ЦКИЙ** — казак...-ы; *казацкий конь* — казак аты.

**КАЗА'ЧЕСТВО** *ср. мн.* нет, *собир.* — казаклар.

**КАЗА'ЧИЙ** — казак...-ы; казаклар...-ы; *казачьи песни* — казак җырлары; *казачий атаман* — казаклар атаманы.

**КАЗА'ЧКА** *ж.* — казак хатын-кызы.

**КАЗАЧО'К** *м.* — 1. *разг. фам.* к. казак; 2. казачок (а. элекке дворян тормыш-көнкүрешендә хезмәтче малай; б. бию исеме; в. шул биюнең көе).

**КАЗАЧО'НОК** *м.* (*мн.* казачата) *разг.* — казак малае, казак улы.

**КАЗА'ШКА** *ж.* — казах хатын-кызы.

**КАЗЕИ'Н** *м. мн.* нет, *хим.* — казеин (сөт составындагы аксым матдәсе).

**КАЗЕИ'НОВЫЙ** *хим. спец.* — казеин(нан ясалган), *казеиновый сыр* — казеин(нан ясалган) сыр.

**КАЗЕМА'Т** *м.*—1. *офиц. устар.* казамат, төрмә; 2. *воен.* казамат (артиллерия һәм авиация утыннан саклану өчен бетон корылма).

**КАЗЕМАТИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. воен.*—казаматлар белән ныгыту.

**КАЗЕМА'ТНЫЙ** *воен.* — казаматлы; *казематное укрепление* — казаматлы ныгытма.

**КАЗЁНКА** *ж. простореч. дореволюц.* — 1. казёнка, аракы кибете; 2. *перен.* казна сата торган аракы.

**КАЗЁННОКО'ШТНЫЙ** *офиц. устар.* — дәүләт акчасына укучы, дәүләт акчасына тәрбияләнүче.

**КАЗЁННЫЙ** — 1. *устар.* казна...-ы; *казённое имущество* — казна милке; 2. *перен.* формаль, бюрократларча; *казённый подход к делу* — эшкә формаль (бюрократларча) мөнәсәбәт; 3. *перен. книж. пренебр.* гади, гадәти; төссез, ярлы; күп чәйнәлгән; *казённый язык* — ярлы тел; *казённые фразы* —

күп чәйнәлгән фразалар. ◇ **На казённый счёт** *разг. шутл.* — казна хисабына, бушлай, бушка, акча түләмичә. **Казённая палата** *офиц. доревол.* — казна палатасы (губернада акчалата салымнарны җыю эше белән идарә иткән учреждение).

**КАЗЁНЩИНА** *ж. мн.* нет, *разг. пренебр.*—формальлек, коры формальлек, коры формализм; *в этой книге ни одной свежей мысли, всё сплошь — казёнщина* — бу китапта бер генә яңа фикер дә юк, барысы да коры формальлек кенә.

**КАЗИНО'** *ср. нескл.* — казино (комарлы уеннар йорты).

**КАЗНА'** *ж. мн.* нет — 1. *офиц. устар.* казна, дәүләт; *имение у него купила казна* — аның имениесен дәүләт (казна) сатып алды; 2. *устар. нар.-поэт. (имущество, деньги)* милек, хәзинә, акча.

**КАЗНАЧЕ'Й** *м. офиц.* — казначей.

**КАЗНАЧЕ'ЙСКИЙ** — 1. *офиц.* казначейлык...-ы; *казначейская должность* — казначейлык вазифасы; 2. *доревол.* казначейство...-ы; *казначейский билет* — казначейство билеты (кәгазь акча).

**КАЗНАЧЕ'ЙША** *ж. разг. устар.* — казначей хатыны.

**КАЗНИ'ТЬ** — 1. *сов.* и *несов.* җәзалап үтерү; 2. *перен. несов. книж.* газаплау, җәзалау; *казнить кого-н. презрением* — нәфрәт күрсәтеп кемне дә булса газаплау; 3. *перен. несов. книж. устар.* хурлау, начар якларын ачу, начар якларын фаш итү; *казнить невежество* — наданлыкны хурлау.

**КАЗНИ'ТЬСЯ** *несов. простореч.* — 1. *страд. устар.* начар яклары ачылу (фаш ителү); *в романе Гончарова „Обыкновенная история" казнится романтизм* — Гончаровның „Обыкновенная история" дигән романында романтизмның начар яклары ачыла (фаш ителә); 2. *(терзать себя, раскаиваясь)* үтә газаплану, үтә борчылу.

**КАЗНОКРА'Д** *м. устар.* — казна талаучы, дәүләт милкен үзләштерүче.

**КАЗНОКРА'ДСТВО** *ср. мн.* нет, *устар.*— казна талау, дәүләт милкен үзләштерү.

**КАРАНДА'ШНЫЙ** — 1. карандаш ...-ы; *карандашное производство* — карандаш производствосы; 2. карандаш белән ясалган; *карандашный рисунок* — карандаш белән ясалган рәсем.

**КАРАНТИ'Н** *м. спец.* — карантин (1. берәр эпидемия булган урыннан килгән кешеләрне, пароходларны, товарларны тикшерү өчен санитария пункты; 2. йогышлы авыру белән авырган яки шундый авырулар белән аралашкан кешене вакытлы рәвештә башкалардан аерып тоту).

**КАРАНТИ'ННЫЙ** — карантин...-ы; *карантинные меры* — карантин чаралары.

**КАРАПУ'З** *м.*, **КАРАПУ'ЗИК** *м.* — 1. *разг. шутл. фам.* тәбәнәк юан бала; 2. *шутл.* карсак юан кеше.

**КАРАСЁВЫЙ** *обл.*, **КАРА'СИЙ** *обл.*, **КАРАСИ'НЫЙ** — табан балык ...-ы; *карасёвая икра* — табан балык уылдыгы; *карасёвая уха* — табан балык шулпасы.

**КАРА'СЬ** *м.* — 1. *зоол.* табан балык, кәрәкә; 2. *перен. просторен.* беркатлы кеше, сүлпән кеше.

**КАРА'Т** *м.* — карат (асылташларны үлчәү өчен кулланыла торган һәм 0,2 граммга тигез булган үлчәү берәмлеге).

**КАРА'ТЕЛЬ** *м. книж. устар.* — җәзалаучы, җәза бирүче.

**КАРА'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.* — җәза бирү...-ы; *карательные меры* — җәза бирү чаралары; ◇ карательный отряд *дорев.* — карательный отряд (крестьяннар яки эшчеләр восстаниесен бастыру өчен хөкүмәт тарафыннан җибәрелгән гаскәри отряд).

**КАРА'ТЬ** *несов. книж.* — җәза бирү, җәзага хөкем итү, җәзалау, җәзага тарту.

**КАРА'ТЬСЯ** *несов. страд. книж.* — җәза бирелү, җәзага хөкем ителү, җәзага тартылу.

**КАРАУ'Л** *м.* — 1. каравыл (кораллы сакчы), каравылчы; 2. каравыл урыны; 3. *межд.* каравыл! (куркынычка очраганда ярдәм сорап кычкыру сүзе). ◇ **Хоть караул кричи** *разг.* — каравыл кычкырырлык булдым: аптырадым инде.

**КАРАУ'ЛИТЬ** *несов.* — 1. саклау, саклап тору; 2. *разг.* көтеп тору, сагалап тору.

**КАРАУ'ЛКА** *ж. простореч.* — к. караульня.

**КАРАУ'ЛЬНАЯ** *в знач. сущ.* — к. караульня.

**КАРАУ'ЛЬНЫЙ** — 1. каравылчы...-ы; *караульная будка* — каравылчы будкасы; 2. *в знач. сущ.* каравылчы.

**КАРАУ'ЛЬНЯ** *ж. спец.* — каравыл өе.

**КАРА'ЧКИ:** на карачках — дүрт аяклапып, мүкәләп, үрмәләп.

**КАРАЧУ'Н:** карачун пришёл — үлде, бетте.

**КАРБА'С** *м. мор.* — карбас (зур көймә).

**КАРБИ'Д** *м. мн.* нет, *хим.* — карбид (углеродның металл яки металлоид белән кушылмасы).

**КАРБО'ВАНЕЦ** *м.* — 1. бер сум (акча); 2. *только мн.* акча.

**КАРБО'ЛКА, КАРБО'ЛОВКА** *ж. мн.* нет, *разг.* — карболка, карбол кислотасы.

**КАРБО'ЛОВАЯ КИСЛОТА'** — карбол кислотасы, фенол.

**КАРБОНА'Р, КАРБОНА'РИЙ** *м. истор.* — карбонар (Италиядә XIX йөз башында оештырылган яшерен революцион оешма члены).

**КАРБОНА'Т** *м.* — карбонат (1. карбонат кислотасы тозы; 2. кислоталы минераллар исеме; 3. *мин.* кара алмаз).

**КАРБОНИЗА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *тех.* — к. карбонизировать.

**КАРБОНИЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. тех.* — карбонлаштыру (1. күмергә әверелдерү, мәсәлән, һавасыз җылыту юлы белән агачны күмергә әверелдерү; 2. пычранган майны агач күмере аша сөзү юлы белән чистарту; 3. *текст.* йон яки ярым йон тукымаларны үсемлек кушылмаларыннан арындыру өчен минераль кислоталар ярдәме белән эшкәртү).

**КАРБОНИ'Т** *м. хим. тех.* — карбонит (көчле шартлагыч матдә, динамит).

**КАРБОРУ'НД** *м. хим.* — карборунд (корыч әйберләрне шомарту, утка чыдам материаллар, чәр ташлары хәзерләү өчен кулланыла торган каты кристаллик матдә).

**КАРБУ'НКУЛ** I *м. мед.* — чуан.

**КАРБУ'НКУЛ** II *м. мин.* — карбункул, кызыл гранат (асылташ).

**КАРБУНКУЛЁЗНЫЙ** *мед.* — чуанлы; *карбункулёзный нарыв* — чуанлы шеш.

**КАРБЮРА'ТОР** *м.* — карбюратор (эчке янулы двигательләрдә карбюрацияләү приборы).

**КАРБЮРА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *хим. тех.* — карбюрация (эчке янулы двигательләрдә сыек ягулыкны һава белән кушып яна торган кушылма булдыру).

**КАРБЮРИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов., хим. тех.* — карбюрацияләү.

**КАРГА'** *ж.* — 1. *обл.* карга; 2. *простореч. бран.* усал карчык, җен карчыгы.

**КА'РДА** *ж. тех.* — карда (мамыкны һәм йонны тарап чистарту өчен корыч инәләрдән ясалган щётка).

**КАРДАМО'Н** *м. мн.* нет, *кулин.* — кардамон (имбирчәләр семьялыгыннан булган үсемлекнең ашка тәм кертү өчен кулланыла торган орлыгы).

**КАРДИНА'Л** *м.* — кардинал (1. католикларда пападан кала иң югары руханилык дәрәҗәсе; 2. *спец.* кызыл бояуның бер төре; 3. *зоол.* Америкада кызыл йонлы кошларның бер төре).

**КАРДИНА'ЛЬНЫЙ** *книж.* — иң мөһим, иң әһәмиятле; *кардинальный вопрос* — иң мөһим мәсьәлә.

**КА'РДНЫЙ** *тех.* — кардалы; *кардная машина* — кардалы машина.

**КАРДО'Н** *м. простореч.* — к. картон 1.

**КАРДО'НКА** *ж.* — к. картонка.

**КАРДО'ННЫЙ** *простореч.* — к. картонный 1.

**КАРЕ'** *ср. нескл. воен. устар.* — каре (төрле яктан булган атаканы кире кайтару өчен пехотаның дүртпочмак булып тезелүе).

**КАРЁЖИТЬ, КАРЁЖИТЬСЯ** *несов.* — к. корёжить, корёжиться.

**КАРЕ'ЛКА** *ж.* — карел хатын-кызы.

**КАРЕ'ЛЫ** *мн.* (*ед.* карел) — кареллар, карел халкы.

**КАРЕ'ЛЬСКИЙ** — 1. карел...-ы; *карельский язык* — карел теле; 2. Карелия...-ы; *карельские леса* — Карелия урманнары.

**КАРЕ'ТА** *ж.* — карета (һәр яктан ябулы сиртмәле арба).

**КАРЕ'ТКА** *ж.* — каретка (1. кечкенә карета; 2. кайбер машиналарда кечкенә барабан, вал).

**КАРЕ'ТНИК** *м. устар.* — 1. сарай, лапас (арбалар кую өчен); 2. карета мастеры.

**КАРИАТИ'ДА** *ж. архит.* — кариатида (балкон, кәрниз кебекләрне терәтеп торгансыман итеп ясалган кеше, бигрәк тә хатын-кыз сыны).

**КА'РИЙ** — 1. (*о цвете глаз*) коңгырт кара; 2. (*о масти лошади*) кара туры.

**КАРИКАТУ'РА** *ж.* — карикатура (1. көлке рәсем; 2. мәсхәрәләү, көлү; *эта картина — карикатура на искусство* — бу картина — сәнгатьне мәсхәрәләү, сәнгатьтән көлү).

**КАРИКАТУРИ'СТ** *м.* — карикатурист, карикатурачы (көлке рәсемнәр ясаучы художник).

**КАРИКАТУ'РИТЬ** *несов. разг. устар.* — көлке итеп сурәтләү.

**КАРИКАТУ'РНЫЙ** — 1. карикатура...-ы; *карикатурный стиль* — карикатура стиле; 2. көлке; *карикатурная внешность* — көлке кыяфәт.

**КАРИКАТУ'РЩИК** *м. разг. фам.* — к. карикатурист.

**КАРИО'З** *м. мед.* — кариоз, тешнең черүе.

**КАРИО'ЗНЫЙ** *мед.* — черек, черегән; *кариозный зуб* — черек теш.

**КАРКА'С** *м. тех.* — каркас (берәр корылманың, әйбернең төп скелеты).

**КА'РКАТЬ** *несов.* — 1. каркылдау, кар-кар кычкыру; 2. *перен. разг. неодобр.* каркылдау, такылдау (киләчәктә туры мөмкин булган начарлык, бәхетсезлек, уңышсызлыклар турында гына сөйләп тору); *будет тебе каркать, поживём, увидим* — юкны каркылдап торма әле, вакыты җиткәч, күрербез.

**КА'РКНУТЬ** *сов. однокр.* — каркылдап кую.

**КА'РЛА** *м. устар.* — к. карлик.

**КА'РЛИК** *м.* — кәрлә (1. бик кечкенә буйлы кеше; 2. *перен.* берәр кеше белән чагыштырганда әһәмияте бик аз яки бер дә әһәмияте булмаган кеше).

**КА'РЛИКОВЫЙ** — кәрлә, бик тәбәнәк; *карликовый дуб* — кәрлә имән, тәбәнәк имән.

**КА'РЛИЦА** *ж. устар.* — кәрлә хатын-кыз.

**КАРМАЗИ'Н** *м. мн.* нет, *истор.* — кармазин (кара-кызыл төстәге сукно).

**КАРМАЗИ'ННЫЙ** *истор.* — 1. кармазин...-ы; *кармазинный цвет* — кармазин төсе; 2. кармазин..., кармазин(нан тегелгән); *кармазинный кафтан* — кармазин чикмән.

**КАРМА'Н** *м.* — кесә. ◇ **Держи карман шире** *разг. фам.* — тот капчыгыңны. **Не лезть за словом в карман** *разг. фам.* — сүз сорап күршегә кермәү, тапкыр булу, сүзгә бай булу.

**КАРМА'ННИК** *м. просторец.* — кесә карагы.

**КАРМА'ННЫЙ** — кесә...-ы; *карманные часы* — кесә сәгате.

**КАРМА'НЧИК** *м. разг.* — кечкенә кесә.

**КАРМАНЬО'ЛА** *ж. мн.* нет, *истор.* — карманьола (1. 1792 елгы француз буржуаз революциясе вакытында чыккан революцион җыр; 2. шул җырга биелә торган танец; 3. якобинецлар киеме).

**КАРМА'ШЕК** *м. разг.* — кечкенә кесә.

**КАРМИ'Н** *м.* — кармин (җете кызыл буяу).

**КАРМИ'ННЫЙ** — җете кызыл.

**КАРНАВА'Л** *м.* — карнавал (маскарад һәм гуляние белән үткәрелә торган халык бәйрәме).

**КАРНАУ'ХИЙ** — к. корноухий.

**КАРНИ'З** *м.* — кәрниз.

**КАРОТЕ'ЛЬ** *ж. мн.* нет, *бот.* — каротель, кыска, тупыйк очлы кишер.

**КАРП** *м. зоол.* — карп (балык).

**КАРПЕ'ТКА** *ж. разг. устар.* — кыска оек, оекбаш.

**КА'РПИЙ** *м.*, **КА'РПИЯ** *ж.* — к. карп.

**КА'РТА** *ж.* — карта; *географическая карта* — географик карта; *игральные карты* — уен карталары; *играть в карты* — карта уйнау. ◇ **Ставить на карту** *перен.* — тәвәккәллеккә бару. **Раскрыть свои карты** *перен.* — үзеңнең планнарыңны, ниятләреңне ачу, яшермәү.

**КАРТА'ВИТЬ** *несов.* — сакауланып сөйләү („р", „л" авазларын бозып сөйләү).

**КАРТА'ВОСТЬ** *ж. мн.* нет — сакаулык („р", „л" авазларын бозып сөйләү).

**КАРТА'ВЫЙ** — сакау („р", „л" авазларын бозып сөйләүче).

**КАРТЁЖ** *ж. мн.* нет, *просторец.* — карта уены.

**КАРТЁЖНИК** *м.*, **КАРТЁЖНИЦА** *ж.* *разг. неодобр.* — картёжник, картёжница, карта уенына бирелгән (кеше).

**КАРТЁЖНЫЙ** *разг. неодобр.* — карта...-ы; *картёжная игра* — карта уены.

**КАРТЕЛИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. экон.* — картельләштерү, картельләргә берләштерү.

**КАРТЕ'ЛЬ** *м.* — картель (1. *полит. устар.* килешү, договор; 2. капиталистик монополияләрнең бер формасы, эре капиталистик промышленность берләшмәсе; 3. *устар.* дуэльгә чакырып җибәрелгән язу).

**КА'РТЕР** *м. тех.* — картер (механизмнарны бозылудан һәм тузаннан саклау җайланмасы).

**КАРТЕ'ЧНЫЙ** — картечлы; *картечная бомба* — картечлы бомба.

**КАРТЕ'ЧЬ** *ж.* — картечь (1. *воен.* эченә күп пуля салынган һәм берьюлы күп кешене яралауга исәп тотып эшләнгән снаряд; 2. *охот.* эре ядрә).

**КАРТИ'НА** *ж.* — 1. (*произведение живописи*) картина, рәсем; 2. кинокартина, фильм; 3. күренеш, картина; *картины природы* — табигать күренешләре, табигать картиналары; *драма в пяти действиях и восьми картинах* — биш пәрдәле һәм сигез күренешле драма. ◇ **Не мост, а картина** — карап туйгысыз матур күпер.

**КАРТИ'НКА** *ж.* — кечкенә рәсем, картинка. ◇ **Не комната, а картинка** — карап туйгысыз матур бүлмә.

**КАРТИ'ННО** *нареч.* — матур булып, картинадагы кебек; *между лесистых и крутых берегов картинно изогнулась река* — урман белән капланган текә ярлар арасыннан елга матур булып боргаланып ага.

**КАРТИ'ННОСТЬ** *ж. мн.* нет — матурлык; ачыклык, образлылык.

**КАРТИ'ННЫЙ** — 1. картиналар...-ы; *картинная галлерея* — картиналар галлереясы; 2. матур, картинадагы кебек, тәэсир калдыра торган, күзгә бәрелеп тора торган; *картинная поза* — матур кыяфәт; 3. образлы; *картинный стиль* — образлы стиль.

**КАРТИ'ШКИ** *ед.* нет — уен картасы.

**КАРТОГРА'ММА** *ж.* — картограмма (билгеле бер территориягә караган статистик мәгълүматларны күрсәтеп ясалган чертёж).

**КАРТО'ГРАФ** *м.* — картограф (картография белгече).

**КАРТОГРАФИ'РОВАТЬ** *несов. спец.* — 1. географик картага кертү; 2. картограммалар төзү.

**КАРТОГРАФИ'ЧЕСКИЙ** *спец.* — карто-

график, картография...-ы; *картографические приёмы* — картография алымнары.

**КАРТОГРА'ФИЯ** *ж. мн.* нет, *спец.* — картография (географик карталар төзү әлымнары турындагы фән).

**КАРТО'Н** *м.* — 1. катыргы; 2. катыргы тартма.

**КАРТОНА'Ж** *м. спец.* — катыргыдан ясалган әйбер.

**КАРТОНА'ЖНЫЙ** — 1. катыргы әйберләр ясау...-ы; *картонажная мастерская* — катыргы әйберләр ясау мастерское; 2. катыргы(дан ясалган); *картонажные изделия* — катыргы әйберләр.

**КАРТО'НКА** *ж.* — 1. катыргы тартма; 2. *разг.* фанера тартма (баш киемнәре, йорт әйберләре салу өчен).

**КАРТО'ННЫЙ** — 1. катыргы(дан ясалган); *картонная коробка* — катыргы тартма; 2. *перен. разг. устар.* нык эшләнмәгән, ялган, уенчык...; *картонный меч* — уенчык кылыч. ◇ **Картонный домик** *книж.* — ышанычсыз нәрсә (һәлак булачагы алдан ук билгеле нәрсә).

**КАРТО'НЩИК** *м. спец.* — картонщик, катыргы ясаучы (эшче); катыргыдан әйберләр ясаучы.

**КАРТОТЕ'КА** *ж. спец.* — картотека (нинди дә булса мәгълүматларны эченә алган карточкалар җыелмасы).

**КАРТОТЕ'КАРЬ** *м. спец.* — картотекарь (картотека белән эш итүче хезмәткәр, картотеканы алып баручы).

**КАРТОФЕЛЕЗАГОТО'ВКА** *ж. офиц.* — бәрәңге хәзерләү.

**КАРТОФЕЛЕКОПА'ЛКА** *ж.*, **КАРТОФЕЛЕКОПА'ТЕЛЬ** *м. с.-х.* — бәрәңге казыгыч, бәрәңге казу машинасы.

**КАТОФЕЛЕСАЖА'ЛКА** *ж.*, **КАРТОФЕЛЕСАЖА'ТЕЛЬ** *м. с.-х.* — бәрәңге утырткыч, бәрәңге утырту машинасы.

**КАРТО'ФЕЛИНА** *ж. разг.* — бер бәрәңге, бер данә бәрәңге.

**КАРТО'ФЕЛЬ** *м. мн.* нет — бәрәңге.

**КАРТО'ФЕЛЬНЫЙ** — бәрәңге...-ы; *картофельная мука* — бәрәңге оны.

**КА'РТОЧКА** *ж.* — карточка (1. фотографиядә төшерелгән рәсем; 2. дүрт почмаклы катыргы кисәге, картотека карточкасы; 3. нормалаштырылган товар яки продукт алу өчен бирелә торган бланк).

**КА'РТОЧНЫЙ** — 1. карта...-ы; *карточная игра* — карта уены; 2. карточкалар...ы; *карточный каталог* — карточкалар каталогы; 3. карточка белән бирелә торган; *карточное масло* — карточка белән бирелә торган май. ◇ **Карточный домик** *разг.* — 1. уен карталарыннан ясалган өй (балалар уены); 2. *перен.* к. картонный домик.

**КАРТО'ШКА** *ж. простореч.* — бәрәңге.

**КАРТУ'З** *м.* — картуз (1. козырёклы баш киеме; 2. *воен. истор.* дары заряды өчен кәгазь пакет; 3. *устар. обл.* бөртекле әйберләр салу өчен кәгазь пакет).

**КАРТУ'ЗНИК** *м. спец.* — картуз ясаучы.

**КАРТУ'ЗНЫЙ** — картуз...-ы; *картузный козырёк* — картуз козырёгы.

**КАРУСЕ'ЛЬ** *ж.* — карусель.

**КАРУСЕ'ЛЬНЫЙ** — карусельдә...; *карусельное катание* — карусельдә әйләнү. ◇ **Карусельный станок** *тех.* — карусель станок (вертикаль, әйләнмә токарный станок).

**КА'РЦЕР** *м. доревол.* — карцер (берәр нәрсәдә гаепләнгән кешене вакытлыча үзен генә ябып тоту өчен бик кечкенә бүлмә).

**КАРЧ** *м.*, **КАРЧА'** *ж. обл. спец.* — суга баткан агач, бүрәнә.

**КАРЬЕ'Р** I. *м.* — карьер (атның иң тиз чабышы). ◇ **С места в карьер** *разг.* — һичбер хәзерлексез, капыл.

**КАРЬЕ'Р** II *м. устар.* — к. карьера.

**КАРЬЕ'Р** III *м.* — карьер (сай яткан казылмаларны казып чыгару урыны).

**КАРЬЕ'РА** *ж.* — карьера (1. нинди дә булса берәр өлкәдә эшчәнлек күрсәтеп, хезмәттә, җәмәгать эшләрендә күтәрелү; 2. *устар.* профессия, хезмәт төре). ◇ **Сделать карьеру** *разг.* — тышкы уңышларга ирешү, эшли торган өлкәдә югары дәрәҗәгә, уңышларга ирешү.

**КАРЬЕРИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *книж.* — карьеризм, карьеристлык (төрле юллар белән тик үзе өчен генә уңыш, алдынгылык казануга омтылу).

**КАРЬЕРИ'СТ** *м.* — карьерист (үзенең шәхси интересларын гына кайгыртучы, үз интересларын иҗтимагый эш интересларыннан югары куючы кеше).

**КАРЬЕРИ'СТКА** *ж.* — карьеристка (к. карьерист).

**КАРЬЕРИСТИ'ЧЕСКИЙ** — карьеристлык...-ы; *из карьеристических соображений* — карьеристлык ниятләреннән чыгып.

**КАРЬЕ'РНЫЙ** — карьера...-ы; *из карьерных соображений* — карьера ниятләреннән чыгып.

**КАРЯ'ГА** *ж.* — к. коряга.

**КАРЯ'ЧИТЬ, КАРЯ'ЧИТЬСЯ** *несов.* — к. корячить, корячиться.

**КАСА'ЕМО** *предлог простореч. обл.* — к. касательно.

**КАСА'ТЕЛЬНАЯ** *мат.* — орынма, орынма сызык.

**КАСА'ТЕЛЬНО** *предлог канц. устар.* — турында, ...-га карата; *касательно нашего дела* — безнең эшебез турында (эшебезгә карата).

**КАСА'ТЕЛЬСТВО** *ср. мн.* нет, *книж.* — катнаш, мөнәсәбәт; *к этому делу он не имеет никакого касательства* — бу эшкә аның бертөрле дә катнашы юк.

**КАСА'ТИК** *м. простореч. обл.* — матурым, сөеклем, аппагым, үскәнем.

**КАСА'ТКА** *ж. обл.* — 1. яр карлыгачы, кәрәшә; 2. к. касатик.

**КАСА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. (*дотрагиваться*) орыну, кагылу, тию; бәрелү; 2. кагылу, кагылып үтү, искә алып китү; *автор касается также вопроса о современном театре* — автор хәзерге театр мәсьәләсенә дә кагылып үтә; 3. бару; *речь у нас касается музыки* — безнең сүзебез музыка турында бара; 4. катнашы булу, карау, кагылу; *вопрос касается вас* — мәсьәлә сезгә карый;

*дело это меня совершенно не касается* — бу эшкә минем бөтенләй катнашым юк. ◇ Что касается *кого-чего*, то..., — ...-га килгәндә, ... килгәндә исә,....

**КА'СКА** *ж.* — каска (металлдан ясалган баш киеме).

**КАСКА'Д** *м.* — 1. шарлавык, шарлама; 2. *спорт.* каскад (аттан төшү алымы); 3. *перен.* муллык, туктаусыз агыш; *каскад слов* — сүзләрнең муллыгы, сүзләрнең туктаусыз агышы.

**КАСКА'ДНЫЙ** — *перен.* әдәпсез, әхлаксыз; *каскадные темы* — әдәпсез темалар.

**КАСКЕ'ТКА** *ж.* — җәйге фуражка.

**КА'ССА** *ж.* — касса (1. акча алу, саклау, бирү урыны; 2. кредит учреждениеләре исеме; *сберегательная касса* — саклык кассасы; 3. учреждениенең барлык акчасы; 4. кыйммәтле әйберләр һәм акча саклау сандыгы; 5. типографиядә хәрефләр тартмасы).

**КАССА'ТОР** *м.* — кассатор (кассация тәртибендә суд хөкемен юкка чыгару турында үтенеч белән мөрәҗәгать итүче).

**КАССАЦИО'ННЫЙ** *право* — кассацион, кассация...-ы; *кассационная жалоба* — кассация жалобасы; *кассационный срок* — кассация срогы.

**КАССА'ЦИЯ** *ж. право* — кассация (1. югары инстанция тарафыннан суд хөкемен юкка чыгару; 2. *разг.* суд хөкемен юкка чыгару турында жалоба). ◇ Кассация выборов — сайлауларны дөрес түгел дип тану һәм аларны юкка чыгару.

**КАССЕ'ТА** *ж.*, **КАССЕ'ТКА** *ж.* — кассета (яктылык үткәрми торган тартма; фотография пластинкаларын саклау өчен кулланыла).

**КАССИ'Р** *м.* — кассир.

**КАССИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.* — кассация ясау, юкка чыгару; *кассировать решение суда* — судның карарын юкка чыгару.

**КАССИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов.* — кассация ясалу, юкка чыгарылу.

**КАССИ'РША** *ж.* — кассирша.

**КА'ССОВЫЙ** — касса...-ы; *кассовая операция* — касса операциясе.

**КА'СТА** *ж.* — каста (1. Һиндстанда һәм кайбер башка Көнчыгыш илләрендә члennарының чыгышына, профессиясенә карап төзелгән һәм башкалар белән аралашмый торган социаль төркем, катлау; 2. *перен.* башкалардан читтә торып үзенчә генә яшәргә маташучы иҗтимагый төркем, катлау).

**КАСТАНЬЕ'ТЫ** *мн.* (*ед.* кастаньета) — кастаньеталар (биегәндә шакылдату өчен бармакларга киелә торган агач шакылдаткычлар).

**КАСТЕЛЯ'НША** *ж.* — кастелянша (больницаларда, тулай торакларда һ. б. эчке кием-салым һәм керләр белән идарә итү хезмәтендәге хатын-кыз).

**КАСТЕ'Т** *м. спец.* — кастет (бармакларга кидерелеп, йодрыкка йомарлана торган корыч корал).

**КАСТО'Р** *м. мн.* нет, *спец.* — кастор (постау сорты).

**КАСТО'РКА** *ж. мн.* нет, *просторец.* — касторка, кастор мае (эч китәрә торган дару).

**КАСТО'РОВЫЙ** I: касторовое масло — кастор мае.

**КАСТО'РОВЫЙ** II — кастор(дан тегелгән); *касторовое пальто* — кастор пальто.

**КАСТРА'Т** *м. книж.* — печелгән ир кеше.

**КАСТРА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет — печү; печелү.

**КАСТРИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.* — печү, печтерү.

**КАСТРИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов.* *страд.* — печелү, печтерелү.

**КАСТРЮ'ЛЬКА** *ж. разг.* — кечкенә кастрюль.

**КАСТРЮ'ЛЯ** *ж.* — кастрюль.

**КАТ** I *м. устар.* — палач.

**КАТ** II *м. мор.* — кат (якорь күтәрү краны).

**КАТАВА'СИЯ** *ж. просторец.* — тәртипсезлек, ыгы-зыгы, шау-шу, чуалчыклык.

**КАТАКЛИ'ЗМ** *м. книж.* — катаклизм (табигатьтә һәм җәмгыятьтә кискен үзгәреш, җимергеч переворот).

**КАТАКО'МБЫ** *мн.* (*ед.* катакомба) — катакомбалар (җир асты коридорлары).

**КАТАЛА'ЖКА** *ж. просторец. пренебр.* — каталажка, төрмә.

**КАТАЛЕ'КТИКА** *ж.* — каталектика (шигырь төзүдә бер алым).

**КАТАЛЕКТИ'ЧЕСКИЙ** — каталектик, каталектикалы; *каталектический стих* — каталектик шигырь.

**КАТАЛЕПСИ'ЧЕСКИЙ** *мед.* — каталепсик; *каталепсический сон* — каталепсик йокы.

**КАТАЛЕ'ПСИЯ** *ж. мн.* нет, *мед.* — каталепсия, катып калу (авыруы).

**КАТАЛЕ'ПТИК** *м.*, **КАТАЛЕПТИ'ЧКА** *ж. мед.* — каталептик, каталепсия белән авыручы.

**КАТА'ЛИЗ** *м. хим.* — катализ (катализаторлар тәэсире белән химик реакцияне тизләтү яки акрынайту).

**КАТАЛИЗА'ТОР** *м. хим.* — катализатор (үзе үзгәрмичә химик реакцияне тизләтүче яки акрынайтучы матдә).

**КАТАЛО'Г** *м.* — каталог (бер төрле предметларның, мәсәлән, китапларның, товарларның һ. б. билгеле бер тәртиптә төзелгән исемлеге).

**КАТАЛОГИЗА'ТОР** *м.* — каталог төзүче.

**КАТАЛОГИЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.* *спец.* — каталогка кертү; каталог төзү.

**КАТАЛОГИЗИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов.* *страд. спец.* — каталогка кертелү; каталог төзелү.

**КАТАЛО'ЖНЫЙ** — каталог...-ы; *каталожная карточка* — каталог карточкасы.

**КАТА'НЬЕ** *ср.* — к. катать, кататься.

**КАТАПУ'ЛЬТА** *ж.* — катапульта (1. *истор.* борынгы заманда таш, ук һ. б. шөйдәту машинасы; 2. *воен. ав.* корабль палубасыннан самолётны очыртып җибәрү өчен җайланма).

**КАТА'Р** *м. мед.* — катар (лайлалы ярының ялкынсынуы).

**КАТАРА'КТ** *м.* — 1. *мед. устар.* к. ка-

тарақта; 2. *тех.* катаракт (пар машиналарында клапанны автоматик ача торган җайланма).

**КАТАРА'КТА** *ж. мед.* — катаракта (күз бәбәге авыруы).

**КАТАРА'ЛЬНЫЙ** — катараль; *катаральное воспаление лёгких* — үпкәнең катараль ялкынсынуы.

**КАТАСТРО'ФА** *ж.* — 1. катастрофа, зур бәхетсезлек, һәлакәт, бәла, каза; 2. *лит.* үзәк вакыйга (драматик әсәрдә чишелү моментыннан элек булган һәм чишелүнең шарты булган үзәк вакыйга).

**КАТАСТРОФИ'ЧЕСКИЙ** — катастрофик, һәлакәтле, бәлале, казалы.

**КАТАСТРОФИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет — катастрофалылык.

**КАТАСТРОФИ'ЧНЫЙ** — к. катастрофический.

**КАТА'ТЬ** *несов.* — 1. тәгәрәтү, тәгәрәтеп йөртү; *катать шары* — шарлар тәгәрәтү; 2. йөртү; *катать детей на лодке* — балаларны көймәдә йөртү; 3. әвәләү, әвәләп ясау; *катать свечи из воску* — балавыздан шәмнәр әвәләү; 4. тәгәрәтү, тәгәрәтеп шомарту; *катать бельё* — кер тәгәрәтү; 5. басу (киез). ◇ **Вспыхнул огонь и пошёл катать по крышам** *простореч.* — ут чыкты да түбәдән түбәгә сикерә башлады.

**КАТА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. тәгәрәү, тәгәрәп йөрү; *шары катаются по бильярду* — шарлар бильярд өстендә тәгәрәп йөриләр; 2. шуу; *кататься на коньках* — коньки шуу; 3. йөрү; *кататься на лодке* — көймәдә йөрү; 4. аунау; *катается от боли по полу* — авыртудан идәндә ауный. ◇ **Кататься со смеху** *разг. фам.* — тәгәри-тәгәри көлү, эче катканчы көлү. **Как сыр в масле катается** — майда йөзә.

**КАТАФА'ЛК** *м.* — катафалк (1. мәет озату арбасы; 2. ябык бина эчендә табут кую өчен калку урын).

**КАТЕГОРИ'ЧЕСКИ** *нареч.* — катгый рәвештә, каты рәвештә, кискен рәвештә, кырт кисеп.

**КАТЕГОРИ'ЧЕСКИЙ** *книж.* — 1. категорик, катгый, кискен; *категорический ответ* — кискен җавап; 2. *филос.* шартларга бәйләнмәгән, шартлар белән чикләнмәгән, шартларга бәйләмичә...; *категорическое суждение* — шартларга бәйләмичә хөкем йөртү.

**КАТЕГОРИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — катгыйлык, кискенлек.

**КАТЕГОРИ'ЧНЫЙ** — категорик, катгый, кискен.

**КАТЕГО'РИЯ** *ж.* — 1. *науч.* категория; *категория времени* — заман категориясе; 2. *книж.* төркем, төр, дәрәҗә.

**КА'ТЕНЬКА** *ж. простореч. шутл. истор.* — катенька (революциягә кадәр Екатерина патша рәсеме төшерелгән 100 сумлык кәгазь акча).

**КА'ТЕР** *м. мор.* (*мн.* катера́) — катер, кечкенә судно.

**КА'ТЕРНЫЙ** — катер...-ы; *катерный машинист* — катер машинисты.

**КА'ТЕТ** *м. мат.* — катет (өчпочмакның туры почмак ясый торган яннарының берсе).

**КАТЕ'ТЕР** *м. мед.* — катетер (сидегә тукталган кешенә сидерү яки сидек юлына дару җибәрү өчен кулланыла торган көпшә).

**КАТЕТЕРИЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. мед.* — катетер кую.

**КАТЕТЕРИЗИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. страд. мед.* — катетер куелу.

**КАТЕХИ'ЗИС** *м.* — катехизис (1. *церк.* сораулар-җаваплар формасында төзелгән дини кагыйдәләр китабы; 2. *книж.* берәр фәннең, һөнәрнең, сәнгатьнең нигезләрен кыскача гына аңлатып биргән популяр кулланмалар исеме; *музыкальный катехизис* — музыка катехизисы; 3. *книж. устар.* нинди дә булса карашларның төп тезисләры; *катехизис декабристов* — декабристларның катехизисы).

**КАТИ'ТЬ** *несов.* — 1. тәгәрәтү, тәгәрәтеп илтү, тәгәрәтеп алып бару, тәгәрәтеп китерү; *катить бочку* — мичкәне тәгәрәтү, тәгәрәтеп илтү, тәгәрәтеп китерү; 2. утыртып йөртү; *катить ребёнка в коляске* — баланы кечкенә арбага утыртып йөртү; 3. *простореч.* элдертү (чаптыру, чаптырып бару); *катить в автомобиле* — автомобильдә элдертү (чаптырып бару).

**КАТИ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. тәгәрәү, тәгәрәп бару, тәгәрәп килү; 2. шуу; *дети катятся на салазках с горы* — балалар таудан чана шуалар; 3. агу, тәгәрәү, тәгәрәп агу; *из глаз катились слёзы* — күзләреннән яшьләр ага иде; 4. *разг.* ашыгып бару, тиз бару; чабып бару; *автомобиль катится по дороге* — автомобиль юлдан чабып бара. ◇ **День катится за днём** — көн артыннан көн үтеп тора. **Луна катится в зимних облаках** — ай кышкы болытлар эченнән йөзеп бара. **Катись, катитесь** *вульг.* — табаныңны ялтырат, үкчәңне күтәр; күзәмә күренмә, эзең булмасын.

**КА'ТКИЙ** — 1. җиңел тәгәрәүчән; 2. *(скользкий)* тайгак, шома, тигез, шуарга уңайлы.

**КАТО'Д** *м. физ.* — катод, тискәре электрод.

**КАТО'ДНЫЙ** *физ.* — катод...-ы; *катодные лучи* — катод нурлары.

**КАТО'К** *м.* — каток (1. коньки шуу өчен ясалган боз мәйданы; 2. *тех.* җирне, юлны тигезләү өчен кулланыла торган күчәрле авыр цилиндр; 3. *спец.* кер тәгәрәтү станогы; 4. *спец.* авыр әйберләрне тәгәрәткәндә кулланыла торган тәгәрәткеч).

**КАТО'ЛИК** *м.* — католик (католик динендәге кеше).

**КАТОЛИКО'С** *м. церк.* — католикос (әрмәннәрнең дин башлыгы).

**КАТОЛИЦИ'ЗМ** *м. мн.* нет — католицизм (католиклар дине).

**КАТОЛИ'ЧЕСКИЙ** — католиклар...-ы; *католическая вера* — католиклар дине.

**КАТОЛИ'ЧЕСТВО** *ср. мн.* нет — к. католицизм.

**КАТОЛИ'ЧКА** *ж.* — католичка (католик динендәге хатын-кыз).

**КА'ТОРГА** *ж. мн.* нет — 1. *дореволюц.* и *загр.* каторга, сөрген (революциягә кадәр җинаятьчеләрне җибәреп авыр эшләр эшләтү урыны); 2. *разг. перен.* каторга, җәһәннәм (үтә авыр тормыш шартлары).

**КАТОРЖА'НИН** *м.*, **КАТОРЖА'НКА** *ж.* — каторжан (каторгада булган кеше, сөргендә булган кеше).

**КА'ТОРЖНИК** *м.*, **КА'ТОРЖНИЦА** *ж.* — 1. *дореволюц.* каторгага җибәрелгән кеше; 2. *простореч. бран.* явыз, кабахәт.

**КА'ТОРЖНЫЙ** *дореволюц.* и *загр.* — 1. каторга...-ы; *каторжные работы* — каторга эшләре; 2. *перен.* түзә алмаслык авыр, газаплы; 3. *в знач. сущ. устар.* — к. каторжник.

**КАТРЕ'Н** *м. лит.* — катрен, дүрт юллы шигырь.

**КАТУ'ШЕЧНЫЙ** — 1. кәтүк...-ы; *катушечное производство* — кәтүк производствосы; 2. *(в виде катушки)* кәтүксыман.

**КАТУ'ШКА** *ж.* — кәтүк, катушка.

**КАТЫ'Ш** *м. простореч.* — түгәрәк кисәк; *восковой катыш* — түгәрәк балавыз кисәге; 2. түгәрәк кискә, бүрәнә кисәге.

**КАТЫШО'М** *нареч. простореч.* — мәтәлчеклэп, мәтәлеп, тәгәрәп.

**КАУЗА'ЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *науч.* — сәбәплелек.

**КАУЗА'ЛЬНЫЙ** — сәбәпле; *каузальная связь* — сәбәпле бәйләнеш.

**КА'УПЕР** *м. горн.* — каупер (домна мичләрендә һава жылыту өчен жайланма).

**КАУ'РКА** *ж. обл.* — бурлы ат.

**КАУ'РЫЙ** *обл. спец.* — бурлы (ат төсе).

**КАУСТИ'ЧЕСКИЙ** — каустик, яндыра торган, көйдерә торган.

**КАУЧУ'К** *м. мн.* нет — каучук (резина ясауга китә торган матдә).

**КАУЧУ'КОВЫЙ** — 1. каучук...-ы; *каучуковое дерево* — каучук агачы; 2. каучук..., резин...; *каучуковая палка* — каучук таяк; резин таяк.

**КАУЧУКОНО'С** *м. бот. тех.* — каучук үсемлеге, каучуклы үсемлек.

**КАФЕ'** *ср. нескл.* — кафе (кофе, чәй, салкын эчемлекләр һәм төрле закускалар сатыла торган кечкенә ресторан).

**КА'ФЕДРА** *ж.* — кафедра (1. укытучы, докладчы өчен ясалган биек урын; 2. югары мәктәптә билгеле бер тармакка керә торган фәннәрне укыту бүлеге; *кафедра истории* — тарих кафедрасы).

**КА'ФЕЛЬ** *м. устар.* — кафель, чынаяк кирпеч.

**КА'ФЕЛЬНЫЙ** — 1. кафель...-ы, чынаяк кирпеч...-ы; *кафельное производство* — кафель производствосы; 2. кафель белән капланган; *кафельная печь* — кафель белән капланган мич.

**КАФЕТЕ'РИЙ** *м.* — кафетерий, кафе, ресторан.

**КАФЕШАНТА'Н** *м. дореволюц.* и *загр.* — кафешантан (әдәпсез җырлар һәм биюләр башкарыла торган ачык сәхнәле кафе, күңел ачу урыны).

**КАФЕШАНТА'ННЫЙ** — 1. кафешантан ...-ы; *кафешантанная певица* — кафешантан җырчысы; 2. *перен.* әдәпсез, оятсыз, әшәке.

**КАФТА'Н** *м.* — чикмән, бөрмәле чикмән.

**КАФТАНИ'ШКО** *ср. простореч.* — чикмән кисәге, начар чикмән.

**КАХЕТИ'НКА** *ж.* — кахетинка, кахетин хатын-кызы.

**КАХЕТИ'НСКИЙ** — 1. кахетин...-ы; *кахетинский язык* — кахетин теле; 2. Кахетия ...-ы; *кахетинские горы* — Кахетия таулары.

**КАХЕТИ'НЦЫ** *мн.* (*ед.* кахетинец) — кахетиннар, кахетин халкы (грузиннар нәселеннән булган бер халык).

**КАЦАВЕ'ЙКА** *ж.* — кацавейка (ачык якалы, мех тотылган кыска кофта).

**КАЧА'ЛКА** *ж.* — 1. качалка, тирбәлмә урындык; 2. *обл. простореч.* бишек; 3. *спорт.* узыш арбасы.

**КАЧА'НИЕ** *ср.* — 1. *только ед.* *(действие)* тирбәлү; тирбәтү; 2. *(отдельное колебание)* тирбәлеш.

**КАЧА'ТЬ** *несов.* — 1. тирбәтү, тибрәтү; *качать колыбель* — бишек тирбәтү; *ветер сильно качает берёзы* — җил каеннарны бик нык тибрәтә; 2. атындыру; *качать на качелях* — таган атындыру; 3. селкү, селкетү, чайкау; *качать головой* — башны селкү, башны чайкау; 4. кулларда йөртү, чөю, чөеп йөртү; *качать юбиляра* — юбилярны чөю; 5. качать итеп чыгару; *качать воду из колодца* — коедан су качать итеп чыгару. ◇ **Качай, качайте** *простореч.* — к. валяй, валяйте.

**КАЧА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. тирбәлү, селкенү; *лодка качается на волнах* — көймә дулкыннар өстендә тирбәлә; 2. атыну; *качаться на качелях* — таган атыну; 3. (*пошатываться на ходу*) алпан-тилпән килү, ава-түнә йөрү.

**КАЧЕ'ЛИ** *ед.* нет — таган (атыну өчен).

**КАЧЕ'ЛЬНЫЙ** — таган...-ы; *качельная доска* — таган тактасы.

**КА'ЧЕСТВЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — 1. югары сыйфатлылык; *качественность товаров* — товарларның югары сыйфатлылыгы; 2. сыйфат; *качественность продукции высока* — продукциянең сыйфаты югары.

**КА'ЧЕСТВЕННЫЙ** *книж.* — 1. сыйфат ягыннан...; *качественный анализ* — сыйфат ягыннан анализ; 2. яхшы сыйфатлы, яхшы сортлы; *качественные стали* — яхшы сыйфатлы (сортлы) корычлар.

**КА'ЧЕСТВЕННОЕ И'МЯ ПРИЛАГА'ТЕЛЬНОЕ** *грам.* — асыл сыйфат.

**КА'ЧЕСТВО** *ср.* — 1. *только ед.* сыйфат; *борьба за качество продукции* — продукциянең сыйфаты өчен көрәш; 2. як; *у этого романа есть одно плохое качество — он очень длинен* — бу романның бер начар ягы бар — ул бик озын; 3. *простореч. обл.* начарлык; *от неё (водки) все качества* — барлык начарлыклар шуннан (аракыдан). ◇ В качестве *кого-чего* — ... буларак; ... булып; ... итеп; *в качестве дру-*

*га* — дустым буларак; *пригласить в качестве директора* — директор итеп чакыру.

**КА'ЧКА** I *ж.* — 1. к. качать; 2. (*колебание судна*) чайкалу, тирбәлү, качка; 3. *обл.* (*колыбель*) бишек.

**КА'ЧКА** II *ж. обл.* — үрдәк.

**КА'ЧКИЙ** *простореч. обл.* — 1. чайкалучан, тирбәлүчән; 2. чалулы, сикәлтәле.

**КАЧНУ'ТЬ** *сов. однокр.* — селкетеп кую, селкетеп җибәрү, селкетеп алу.

**КАЧНУ'ТЬСЯ** *сов. однокр.* — селкенеп кую, тирбәлеп кую.

**КА'ША** *ж.* — 1. ботка; *гречневая каша* — карабодай боткасы; 2. *перен.* (*путаница*) буталчыклык, тәртипсезлек. ◇ **Заварить кашу** *разг. перен.* — мәшәкатьле эш башлау. **Расхлёбывать кашу** *разг. перен.* — бёрәр катлаулы, буталчык, күңелсез эшне ерып чыгу. **Каши не сваришь** *с кем разг. перен.* — эшен пешмәс, борчагың пешмәс. **Мало каши ел** *перен. простореч. шутл.* — авызыңнан ана сөте кипмәгән (аз тәҗрибәле). **С кашей съем** *разг. фам.* — кирәген бирермен. **Каши просят** (сапоги, башмаки и др) *разг. шутл.* — ашарга сорый (тузган, ертылган итек, ботинка турында көләп әйтелә).

**КАШАЛО'Т** *м. зоол.* — кашалот (кит балыгының бер төре).

**КАШЕВА'Р** *м. спец.* — аш пешерүче (артельдә яки гаскәри частьта).

**КАШЕВА'РИТЬ** *несов. спец.* — аш пешереп тору, аш пешерүче булып хезмәт итү.

**КА'ШЕЛЬ** *м. мн.* нет — 1. ютәл, йөткерү, йөткерек; *сухой кашель* — коры ютәл; 2. *разг.* (*болезнь*) ютәл авыруы.

**КАШЕМИ'Р** *м.* — кәшемир (юка йон тукыма).

**КАШЕМИ'РОВЫЙ** — кәшемир(дән тегелгән); *кашемировый халат* — кәшемир халат.

**КА'ШИЦА** *ж.* — сыек ботка.

**КА'ШКА** *ж.* — 1. *разг.* ботка; 2. *разг. бот.* тукранбаш, тәкә мөгезе, өчьяфрак.

**КАШКАРА'** *ж. мн.* нет, *бот.* — кашкар гөле.

**КА'ШЛЯНУТЬ** *сов. однокр.* — тамак кырып кую; *чтобы напомнить о себе, он слегка кашлянул* — үзенең барлыгын белдерү өчен ул әкрен генә тамак кырып куйды.

**КА'ШЛЯТЬ** *несов.* — йөткерү, ютәлләү. ◇ **Кашлять кровью** — кан төкерү.

**КАШНЕ'** *ср. нескл.* — кашне, шарф, муен яулыгы.

**КАШТА'Н** *м. бот.* — каштан (агачы һәм җимеше).

**КАШТА'НОВЫЙ** — 1. каштан...-ы; *каштановое дерево* — каштан агачы; 2. аксыл коңгырт; *каштановые волосы* — аксыл коңгырт чәч.

**КАЩЕ'Й** *м.* — к. кощей.

**КАЮ'К** I *м. спец.* — каек, көймә.

**КАЮ'К** II *м. нескл. простореч.* — бетте, дөмекте, тончыкты, һәлак булды.

**КАЮ'ТА** *ж.* — каюта, бүлмә (пароходта).

**КАЮ'Т-КОМПА'НИЯ** *ж.* — кают-компания (корабльдә пассажирларның, ә хәрби судноларда комсоставның ашау-эчүе, ял итүе h. б. өчен хезмәт итә торган бүлмә).

**КА'ЯТЬСЯ** *несов.* — 1. үкенү, үз-үзен шелтәләү; 2. тәүбә итү, кабатлап эшләмәскә сүз бирү.

**КВАДРА'НТ** *м.* — квадрант (1. *мат.* түгәрәкнең дүрттән бер өлеше; 2. *тех.* артиллериядә төзәү приборы; 3. планеталарның биеклеген үлчәү өчен кулланылган борынгы астрономик прибор; 4. озынлык берәмлеге; җир шары меридианының дүрттән бере — 10 000 *км* чамасында).

**КВАДРА'Т** *м.* — квадрат (1. *мат.* тигезъяклы турыпочмаклык; 2. *мат.* нинди дә булса санны үз-үзенә тапкырлаудан килеп чыккан тапкырчыгыш; 3. *тип.* китапны биткә салганда үлчәү берәмлеге). ◇ **В квадрате** *перен. разг. шутл.* — икеләтә, үтә; *дурак в квадрате* — икеләтә тиле, үтә тиле (шыр тиле).

**КВАДРА'ТИК** *м.* — кечкенә квадрат.

**КВАДРАТНО-ГНЕЗДОВА'Я ПОСА'ДКА** — квадратлап-оялап утырту.

**КВАДРА'ТНЫЙ** — квадрат...-ы; *квадратный метр* — квадрат метр; *квадратные скобки* — квадрат җәяләр.

**КВАДРАТУ'РА** *ж.* — квадратура (1. квадрат берәмлекләр, мәсәлән, квадрат метрлар, квадрат сантиметрлар, белән үлчәнә торган мәйданның зурлыгы; *квадратура комнаты* — бүлмәнең квадратурасы; 2. *астр.* берәр планетаның, мәсәлән, Айның, Җир белән Кояш арасындагы сызыкка карата туры почмак ясаган вакыттагы хәле). ◇ **Квадратура круга** *перен.* — чишелеше мөмкин булмаган һәрбер мәсьәлә.

**КВАДРИЛЛИО'Н, КВАДРИЛЬО'Н** *м. мат.* — квадриллион (миллионның дүртенче дәрәҗәсе; 1 цифрыннан соң 24 нуле булган сан).

**КВА'КАНЬЕ** *ср. мн.* нет — 1. бака бакылдавы; 2. *обл.* үрдәк бакылдавы.

**КВА'КАТЬ** *несов.* — бакылдау (бака).

**КВАКУ'ША, КВА'КУШКА** *ж. обл. нар.-поэт.* — бака-бакылдык (әкиятләрдә).

**КВА'КША** *ж. зоол.* — агач бакасы.

**КВАЛИТАТИ'ВНЫЙ** *науч.* — сыйфат ягыннан...; *квалитативное определение* — сыйфат ягыннан билгеләмә.

**КВАЛИФИКАЦИО'ННЫЙ** — квалификация...-ы; *квалификационная комиссия* — квалификация комиссиясе.

**КВАЛИФИКА'ЦИЯ** *ж.* — 1. к. квалифицировать; 2. квалификация (а. *торг.* товарларның сыйфатларын һәм сортларын бәяләү һәм билгеләү; б. эшкә, хезмәткә яраклылык, хәзерлек дәрәҗәсе); 3. профессия; *приобрести квалификацию токаря* — токарьлыкка өйрәнү, токарь профессиясен үзләштерү.

**КВАЛИФИЦИ'РОВАННЫЙ** — 1. югары квалификацияле, тәҗрибәле; 2. махсус белем сорый торган; *квалифицированный труд* — махсус белем сорый торган хезмәт. ◇ **Квалифицированное преступление** — аеруча авыр җинаять. **Квалифицированное большинство** (голосов) — билгеләнгән норма-

дан ким булмаган күпчелек (тавыш биргәндә).

**КВАЛИФИЦИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. книж.* — квалификацияләү (1. белеме ягыннан берәр эшне алып баруга хәзерлек дәрәҗәсен тикшерү; 2. берәр яктан бәя бирү).

**КВАЛИФИЦИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. страд. книж.* — квалификацияләнү.

**КВАНТ** *м.*, **КВА'НТА** *ж. физ.* — квант (нинди дә булса берәр энергиянең иң кечкенә кисәкчәсе).

**КВАНТИТАТИ'ВНЫЙ** *науч.* — сан ягыннан...; *квантитативное определение* — сан ягыннан билгеләмә.

**КВА'НТОВЫЙ** *физ.* — квант...-ы; *квантовая теория* — квант теориясе.

**КВА'РТА** *ж.* — кварта (1. кайбер илләрдә бөртекле һәм сыек әйберләр үлчәве, гадәттә бер литрдан аз гына артыграк; 2. *муз.* диатоник гамманың дүртенче баскычы; 1 һәм 4 баскычлар арасындагы интервал; 3. *спорт.* фехтованиедә — каршы якның һөҗүмен кире кайтару алымнарының берсе).

**КВАРТА'Л** *м.* — квартал (1. шәһәрнең дүрт яктан урам белән чикләнгән өлеше; 2. урамның ике чат арасындагы өлеше; 3. *офиц. канц.* отчёт елының дүрттән бер өлеше (өч ай); 4. *спец.* урман хуҗалыгында квадрат формалы участокларның берсе).

**КВАРТА'ЛЬНЫЙ** — 1. квартал...-ы; *квартальный отчёт* — квартал отчёты; 2. *в знач. сущ. разг. истор.* квартальный (шәһәрнең билгеле бер өлешендә күзәтчелек итүче полицейский, надзиратель).

**КВАРТЕ'Т** *м. муз.* — квартет (1. дүрт тавыш яки дүрт инструмент өчен язылган музыка әсәре; 2. шундый әсәрнең башкарылуы; 3. дүрт кешелек музыкантлар группасы).

**КВАРТИ'РА** *ж.* — 1. квартира, торак; 2. квартирада торучылар; 3. *только мн.* квартиралар (гаскәри частьның урнашкан урыны); *войска перешли на зимние квартиры* — гаскәрләр кышкы квартираларга күчтеләр. ◇ **Главная квартира** — баш квартира (сугыш вакытында баш командующийның үз штабы белән урнашкан урыны).

**КВАРТИРА'НТ** *м.* — квартирант, квартирачы, фатирчы, квартирада торучы.

**КВАРТИРА'НТКА** *ж.* — квартирантка, квартирачы, фатирчы, квартирада торучы хатын-кыз.

**КВАРТИРМЕ'ЙСТЕР** *м. воен. устар.* — квартирмейстер (гаскәрләрне азык, квартира белән тәэмин итү эшләрен башкаручы).

**КВАРТИ'РНИК** *м.*, **КВАРТИ'РНИЦА** *ж. устар.* — өйдә эшләүче һөнәрче.

**КВАРТИ'РНЫЙ** — квартира...-ы; *квартирная плата* — квартира хакы.

**КВАРТИРОВА'ТЬ** *несов.* — 1. *устар. разг.* квартирада тору; 2. *воен.* урнашу; *полк квартировал в селе* — полк авылда урнашкан иде.

**КВАРТИРОНАНИМА'ТЕЛЬ** *м. офиц.* — квартира алучы.

**КВАРТИРОХОЗЯ'ИН** *м.*, **КВАРТИРОХОЗЯ'ЙКА** *ж. офиц.* — квартира хуҗасы (квартираның исемендә булган кеше).

**КВАРТИРЬЕ'Р** *м. воен.* — квартирьер (гаскәрләр бер урыннан икенче урынга күчкәндә аларга алдан квартиралар хәзерләп торучы хәрби кеше).

**КВАРТПЛА'ТА** *ж.* — квартира хакы.

**КВАРЦ** *м. мн.* нет, *мин.* — кварц (техникада киң кулланыла торган минерал, кремнезём окисе).

**КВА'РЦЕВЫЙ** — 1. кварц...-ы, кварц...; *кварцевые породы* — кварц токымнары; *кварцевая лампа* — кварц лампа; 2. кварцлы; *кварцевый песок* — кварцлы ком.

**КВАРЦИ'Т** *м. мн.* нет, *мин.* — кварцит (цементлашкан кварцлы комнан торган тау токымы).

**КВАС** *м.* — куас.

**КВА'СИТЬ** *несов.* — әчетү; оету; *квасить тесто* — камыр әчетү; *квасить молоко* — катык оету.

**КВАСНО'Й** — 1. куас...-ы; *квасная бутылка* — куас шешәсе; 2. куастан хәзерләнгән; *квасная кисель* — куас кесәле. ◇ **Квасной патриотизм** *книж. ирон.* — токмач патриотизмы (милли көнкүрешнең вак-төяк үзенчәлекләрен сакларга тырышу, шуларга ябышып яту).

**КВАСОВА'Р** *м. спец.* — куас кайнатучы, куас ясаучы.

**КВАСОВА'РНЫЙ** *спец.* — куас кайнату ...-ы; *квасоварное производство* — куас кайнату производствосы.

**КВАСОВА'РНЯ** *ж.* — куас кайнату урыны.

**КВАСО'К** *м. разг.* — 1. куас; 2. *обл.* әчкелтем тәм.

**КВАСЦЕВА'ТЬ, КВАСЦОВА'ТЬ** *несов. спец.* — 1. ачуташка туендыру; 2. ачуташ эремәсендә чылату.

**КВАСЦЕВА'ТЬСЯ, КВАСЦОВА'ТЬСЯ** *несов. страд. спец.* — 1. ачуташка туендырылу; 2. ачуташ эремәсендә чылатылу.

**КВАСЦО'ВЫЙ** — ачуташ...-ы; *квасцовый раствор* — ачуташ эремәсе.

**КВАСЦЫ'** *ед.* нет — ачуташ.

**КВАШЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — к. квасить.

**КВАШЕНИ'НА** *ж. мн.* нет — 1. *разг.* әче кәбестә; 2. *с.-х.* әчетелгән үсемлек сабаклары (мал азыгы өчен).

**КВА'ШЕНЫЙ** *спец.* — әче; әчеткән; *квашеная капуста* — әче кәбестә, әчеткән кәбестә.

**КВАШНЯ'** *ж.* — 1. күәс, күәс чиләге; 2. әче камыр; 3. *перен. простореч. пренебр.* җебегән (кеше), ачык авыз.

**КВЁЛЫЙ** *обл.* — 1. көпшәк, йомшак; *яблоко крепче, груша квелее* — алма катырак, груша йомшаграк; 2. йоны коелган, шәрәләнгән; *квёлые индюшки* — йоны коелган күркәләр; 3. *перен.* чирләшкә, авыру, зәгыйфь.

**КВЕ'РХУ** *нареч.* — өскә, өскә таба; югарыга, югарыга таба.

**КВИЕТИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *книж.* — квиc-

тизм (язмышка суфыйларча буйсыну; тормышка пассив мөнәсәбәт).

**КВИЕТИ'СТ** *м. книж.* — квиетист (язмышка суфыйларча буйсынган кеше, тормышка пассив мөнәсәбәттәге кеше).

**КВИЕТИ'ЧЕСКИЙ** *книж.* — квиетистларча...; *квиетический взгляд на вещи* — мәсьәләләргә квиетистларча караш.

**КВИ'НТА** *ж.* — квинта (1. *муз.* диатоник гаммада бишенче баскыч; 2. *муз.* кайбер музыка коралларының ин нечкә кылы; 3. *спорт.* фехтованиедә — каршы якның һөҗүмен кире кайтару алымнарының берсе).

**КВИНТЕ'Т** *м. муз.* — квинтет (1. биш тавыш яки биш инструмент өчен язылган музыка әсәре; 2. шундый әсәрнең башкарылуы; 3. *собир.* квинтетны башкаручы музыкантлар).

**КВИНТЭССЕ'НЦИЯ** *ж. книж.* — квинтэссенция, нигез, төп үзлек.

**КВИПРОКВО'** *ср. нескл.* — квипрокво (берәр кешене, төшенчәне яки әйберне икенчесе белән бутау).

**КВИТ** и **КВИ'ТА** *в знач. сказ.* — 1. исәп-хисап бетте; *я с тобой квит* — минем синең белән исәп-хисабым бетте; 2. *устар.* шуның белән эш бетәр, шуның белән вәссәлам; *забудут — и квит* — онытырлар — һәм шуның белән вәссәлам.

**КВИТАНЦИО'ННЫЙ** — квитанция ...-ы; *квитанционная книжка* — квитанция кенәгәсе.

**КВИТА'НЦИЯ** *ж.* — квитанция (акча яки башка берәр нәрсә алу турында бирелә торган рәсми расписка).

**КВИ'ТЫ** *в знач. сказ.* — к. квит.

**КВО'ЛЫЙ** *обл.* — к. квёлый 1 и 3.

**КВО'РУМ** *м.* — кворум (җыелышның тулы хокуклы булуы өчен җитәрлек катнашучылар саны).

**КВО'ТА** *ж. экон. полит.* — квота, өлеш, процент, рөхсәт ителә торган норма.

**КВОТА'ЦИЯ** *ж. экон. полит.* — берәр нәрсәнең квотасын, өлешен, процентын билгеләү.

**КВО'ХТАТЬ** *несов. обл.* — 1. кыртлау, чырлау (тавык турында); 2. *перен. фам.* сукрану, зарлану, уфылдау.

**КЕ'ГЕЛЬ** *м.* — к. кегль.

**КЕ'ГЕЛЬБАН** *м. спорт.* — кегельбан (кегли уены уйнала торган урын).

**КЕ'ГЕЛЬНЫЙ** — кегли...-ы; *кегельный шар* — кегли шары.

**КЕГЛЬ** *м. тип.* — кегль (типография хәрефләренең зурлыгы).

**КЕ'ГЛЯ** *ж. спорт.* — 1. кегли таягы; 2. *только мн.* кегли уены (билгеле бер ераклыкта бастырып куелган кегли таякларын тәгәрәтеп җибәргән агач шар белән бәрдереп аударудан гыйбарәт булган уен).

**КЕДР** *м. бот.* — эрбет чикләвеге агачы.

**КЕДРО'ВЫЙ** — эрбет ...-ы; *кедровый орех* — эрбет чикләвеге (вак чикләвек).

**КЕЙФ** *м. шутл.* — кәеф-сафа; *предаваться кейфу* — кәеф-сафага бирелү.

**КЕЙФОВА'ТЬ** *несов. шутл.* — кәеф-сафага бирелү, вакытны кәеф-сафада үткәрү, кәеф-сафа сөрү.

**КЕКС** *м.* — кекс (йөзем салып пешерелгән татлы күмәч).

**КЕЛА'РЬ** *м. церк.* — келарь (монастырьда хуҗалык эшләре белән идарә итүче монах).

**КЕ'ЛЕЙКА** *ж. церк.* — кечкенә хөҗрә.

**КЕЛЕ'ЙНИК** *м.*, **КЕЛЕ'ЙНИЦА** *ж. церк.* — 1. архиерей хезмәтчесе, игумен (игуменья) хезмәтчесе; 2. хөҗрәдә яшәүче.

**КЕЛЕ'ЙНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *разг.* — яшеренлек, астыртынлык.

**КЕЛЕ'ЙНО** *нареч.* — яшерен рәвештә, астыртын рәвештә.

**КЕЛЕ'ЙНЫЙ** — 1. хөҗрә...-ы; *келейные правила* — хөҗрә кагыйдәләре; 2. *перен.* яшерен, астыртын; *сделать что-нибудь келейным образом* — берәр нәрсәне яшерен рәвештә эшләү.

**КЕ'ЛЬНЕР** *м.*, **КЕ'ЛЬНЕРША** *ж. загр.* — ресторан хезмәтчесе.

**КЕ'ЛЬНЯ** *ж. тех.* — штукатур калагы, ташчы калагы (известь, цемент болгату һәм чумырып алу өчен кулланыла торган калак).

**КЕ'ЛЬТСКИЙ** — кельт...-ы; *кельтский язык* — кельт теле.

**КЕ'ЛЬТЫ** *мн.* (*ед.* кельт) — кельтлар, кельт халкы (Көнбатыш Европада яшәгән борынгы халыкларның берсе).

**КЕ'ЛЬЯ** *ж.* — 1. *церк.* хөҗрә (монах бүлмәсе); 2. *перен.* аерым кечкенә бүлмә.

**КЕНА'П** *м.* — к. кенаф.

**КЕНА'Р, КЕНА'РЬ** *м.* — ата кенәри (кош).

**КЕНА'Ф** *м. бот.* — кенаф (Урта Азия киндере — үсемлек).

**КЕНГУРО'ВЫЙ** — көнгерә...; *кенгуровая шуба* — көнгерә тун.

**КЕНГУРУ'** *м. нескл. зоол.* — көнгерә.

**КЕНДЫ'РЬ** *м. мн.* нет, *бот.* — киндер.

**КЕНТА'ВР** *м. миф.* — кентавр, ярымкеше-ярымат (борынгы грекларда мифик зат).

**КЕ'НЬГИ** *мн.* (*ед.* кеньга) *обл.* — кеньги (болан тиресеннән эшләнгән җылы аяк киеме).

**КЕ'ПИ** *ср. нескл.* — кепи (XIX гасырда фуражканың бер төре).

**КЕ'ПКА** *ж. разг.* — кепка (баш киеме).

**КЕ'ПОЧНЫЙ** *разг. спец* — кепка...-ы; *кепочный материал* — кепка материалы.

**КЕРА'МИКА** *ж. мн.* нет, *спец.* — керамика (1. балчыктан ясалган әйберләр; 2. чүлмәк производствосы).

**КЕРА'МИКОВЫЙ, КЕРАМИ'ЧЕСКИЙ** *спец.* — керамика...-ы; *керамическое производство* — керамика производствосы.

**КЕРОГА'З** *м.* — керогаз (керосин ягып аш пешерү һәм су кайнату өчен кулланыла торган тавышсыз примусның бер төре).

**КЕРОСИ'Н** *м. мн.* нет — керосин.

**КЕРОСИ'НКА** *ж. разг.* — керосинка (1. аш пешерү приборы; 2. керосин савыты).

**КЕРОСИ'ННЫЙ** — керосин...-ы; *керосинный запах* — керосин исе.

**КЕРОСИ'НОВЫЙ** — керосин...-ы; керосин белән...; *керосиновая лампа* — керосин лампасы; *керосиновое освещение* — керосин белән яктырту.

**КЕРОСИ'НЩИК** *м. спец.* — керосинчы, керосин сатучы.

**КЕ'САРЬ** *м. книж. устар.* — кайсар, патша.

**КЕССО'Н** *м. тех.* — кессон (су үткәрми торган зур камера; елга яки диңгез төбенә төшеп эшләгәндә файдаланыла).

**КЕССО'ННЫЙ** *тех.* — кессон белән эшләнә торган.

**КЕССО'НЩИК** *м. спец.* — кессончы (кессон белән эшләнә торган эшләр белгече).

**КЕ'ТА** *ж. зоол.* — кета (балык).

**КЕ'ТОВЫЙ** — кета...-ы; *кетовая икра* — кета икрасы.

**КЕФА'ЛЬ** *ж. зоол.* — кефаль (вак диңгез балыгының бер төре).

**КЕФИ'Р** *м.* — кефир (сөттән әчетеп ясалган катыксыман куе эчемлек).

**КЕФИ'РНЫЙ** — 1. кефир...-ы; *кефирный вкус* — кефир тәме; 2. кефир ясый торган; *кефирное заведение* — кефир ясый торган урын.

**КИБИ'ТКА** *ж.* — 1. көймәле арба; 2. *устар.* арба көймәсе; 3. *(переносное жилище у кочевых народов)* тирмә.

**КИВА'ТЬ** *несов.* — 1. *(головой)* селкү, чайкау, селкеп ишарә итү, баш кагу; 2. сылтау, үз гаебенне бүтән кешегә аудару; *Иван кивает на Петра, а Пётр на Сидора* — Иван Пётрга сылтый, ә Пётр — Сидорга. ◇ **Кивать пальцем** *кому устар.* — бармак белән чакыру.

**КИ'ВЕР** *м. воен. дореволю.* — кивер (электә гаскәриләрнең озынча түгәрәк баш киеме).

**КИВНУ'ТЬ** *сов. однокр.* — (башны) селкеп куйю, (башны) чайкап кую, (баш) кагу.

**КИВО'К** *м.* — баш белән ымлап күрсәтү (котлау, ризалык белдерү яки берәр нәрсәгә күрсәтү өчен).

**КИДА'ТЬ** *несов. разг.* — к. бросать 1, 3, 4.

**КИДА'ТЬСЯ** *несов. разг.* — к. бросаться.

**КИ'ДКА** *ж. обл. спец.* — 1. к. кидать; 2. *(порция кидаемого)* ташлам, бер ташлам.

**КИЗИ'Л, КИЗИ'ЛЬ** *м. мн.* нет, *бот.* — кизил (кизил агачы һәм аның җимеше).

**КИЗИ'ЛЕВЫЙ, КИЗИ'ЛОВЫЙ** — кизил...-ы; *кизиловое варенье* — кизил вареньесы.

**КИЗИ'ЛЬНИК** *м. мн.* нет — 1. кизил куагы; 2. кизил әрәмәсе; 3. кизил агачы (столяр материалы буларак).

**КИЗЯ'К** *м. обл.* — тизәк, тизәк кирпеч (ягулык өчен).

**КИЗЯ'КОВЫЙ, КИЗЯ'ЧНЫЙ** *обл.* — тизәк...; *кизячное топливо* — тизәк ягулык.

**КИЙ** *м.* — 1. кий, бильярд таягы; 2. *обл.* чукмарлы таяк.

**КИ'КА** *ж. истор.* и *обл.* — к. кичка.

**КИКИ'МОРА** *ж.* — 1. *миф.* хатын-кыз сурәтендәге бичура; 2. *(смешно одетый)* сәвәләй; 3. *просторечн. неодобр. (сумрачный)* караңгы чырайлы, имәнеч, килбәтсез (кеше).

**КИЛ** *м.* — селтеле акбалчык (сабын составына керә).

**КИЛА'** *ж. обл.* — 1. бүсер, бүсер шеше; 2. оры (агачта яки үсемлек тамырларында була торган шеш).

**КИЛЕВО'Й** — буйга...; буйга таба; *килевая качка* — буйга чайкалу, буйга таба чайкалу.

**КИ'ЛЕЧНЫЙ** — 1. килька...-ы; *килечный промысел* — килька промыселы; 2. килька тота торган; *килечные сети* — килька тота торган ятьмә.

**КИЛО'** *ср. нескл.* — кило, килограмм.

**КИЛОВА'ТТ** *м.* — киловатт (электр тогы җегәрлеген үлчәү берәмлеге). ◇ **Киловатт-час** — киловатт-сәгать (электр энергиясен үлчәү берәмлеге).

**КИЛОГРА'ММ** *м.* — килограмм (1000 грамм).

**КИЛОГРАММЕ'ТР** *м. физ.* — килограмметр (бер килограммлы авырлыкны бер метр биеклеккә күтәрү өчен китә торган көчкә тигез булган үлчәү берәмлеге).

**КИЛОГРА'ММОВЫЙ** — бер килограммлы, бер килограмм авырлыгындагы; *килограммовая гиря* — бер килограммлы гер.

**КИЛОМЕ'ТР** *м.* — километр (1000 метр).

**КИЛОМЕ'ТРО'ВЫЙ** — бер километрлы, бер километр озынлыгындагы; *километровое расстояние* — бер километрлы ара.

**КИЛОУА'ТТ** *м. физ. тех.* — к. киловатт.

**КИЛЬ** *м. мор.* — киль (корабль корпусының аскы буй өрлеге).

**КИЛЬВА'ТЕР** *м. мор.* — кильватер (пароход яки корабльнең артында калып бара торган эз).

**КИЛЬВА'ТЕРНЫЙ** — кильватерлы, бербер артлы (тезелеп бара торган); *кильватерная колонна* — кильватерлы колонна (бер-бер артлы тезелеп бара торган суднолар колоннасы).

**КИ'ЛЬКА** *ж.* — килька (балык).

**КИМВА'Л** *м. истор.* — кимвал (ике металл тәлинкәдән гыйбарәт музыка коралы). ◇ **Кимвал звенящий или бряцающий** *книж. устар. ирон.* — тантаналы тонда сөйләнгән, ләкин сай эчтәлекле речь.

**КИМО'ГРАФ** *м. спец.* — кимограф (1. төрле физиологик процессларның барышын график рәвештә язу приборы; 2. экспериментал фонетикада авазларның көкресен язу приборы).

**КИМОНО'** *ср. нескл.* — кимоно (халатсыман киң кием).

**КИНАМО'Н** *м. поэт. устар.* — дарчин.

**КИНГСТО'Н** *м. мор.* — кингстон (корабльнең су астындагы өлешендә су кертә һәм чыгара торган тишекләрне ябa торган клапан).

**КИНДЕРБАЛЬЗА'М** *м. мн.* нет — киндербәлзәм, киндербәлсән (спиртлы эчемлек).

**КИНЕМА'ТИКА** *ж. мн.* нет, *мех.* — кинематика (механиканың хәрәкәтләр турындагы бүлеге).

**КИНЕМАТИ'ЧЕСКИЙ** — кинематик, кинематика...-ы.

**КИНЕМАТО'ГРАФ** *м.* — кинематограф (1. хәрәкәтләнә торган сурәтләрне экранда күрсәтү приборы; 2. кино).

**КИНЕМАТОГРАФИ'СТ** *м.* — кинематографист (кинематографиядә эшләүче).

**КИНЕМАТОГРАФИ'ЧЕСКИЙ** — 1. кинематография...-ы; *кинематографическая промышленность* — кинематография промышленносте; 2. кинематографик, кинокартинадагы шикелле; *с кинематографической быстротой* — кинематографик тизлек белән, кинокартинадагы шикелле тизлек белән (бик тиз).

**КИНЕМАТОГРА'ФИЯ** *ж. мн.* нет — кинематография (кинофильмнар эшләп чыгару промышленносте һәм шуларны экранда күрсәтү сәнгате).

**КИНЕ'ТИКА** *ж. мн.* нет, *мех.* — кинетика (динамикада көчләрнең хәрәкәткә тәэсире турындагы бүлек).

**КИНЕТИ'ЧЕСКИЙ** *мех.* — кинетик, кинетика,..-ы; *кинетическая энергия* — кинетик энергия.

**КИНЖА'Л** *м.* — кинжал, хәнҗәр.

**КИНЖА'ЛЬНЫЙ** — хәнҗәр (кинжал)...-ы; хәнҗәр (кинжал) белән ясалган; *кинжальная рана* — хәнҗәр ярасы. ◇ **Кинжальное действие** *воен.* — якыннан торып эш итү (мәсәлән, ату).

**КИНО'** *ср. нескл.* — 1. кино; *что сегодня идет в кино* — бүген кинода нәрсә бара? 2. к. кинематография.

**КИНОАППАРА'Т** *м.* — киноаппарат, кино аппараты (кинофильмнар күрсәтү яки киносъёмкалар төшерү өчен кулланыла торган аппарат).

**КИНОАКТЁР** *м.* — киноактёр, кино артисты.

**КИНОАКТРИ'СА** *ж.* — киноактриса, кино артисткасы.

**КИНОАРТИ'СТ** *м.* — кино артисты.

**КИНОАРТИ'СТКА** *ж.* — кино артисткасы.

**КИНОВА'РНЫЙ** — киноварь...-ы; *киноварные руды* — киноварь рудалары.

**КИ'НОВАРЬ** *ж.* — киноварь (1. *мин.* кызыл төстәге минерал — күкертле терекөмеш; 2. *хим.* шул минералдан ясалган кызыл буяу).

**КИНОВЕ'ДЕНИЕ** *ср. мн.* нет — кино белеме (кино сәнгате турындагы фән).

**КИНОВЕ'ДЧЕСКИЙ** — кино белеме...-ы; *киноведческий факультет* — кино белеме факультеты.

**КИНОКАРТИ'НА** *ж.* — кинокартина, кино картинасы.

**КИНОЛЕ'НТА** *ж.* — кинолента, кино лентасы.

**КИНОЛО'ГИЯ** *ж. мн.* нет, *спец.* — кинология (зоологиянең этләр һәм аларны үрчетү турындагы бүлеге).

**КИНОМЕХА'НИК** *м.* — киномеханик (кинофильмнар күрсәтүче белгеч).

**КИНООПЕРА'ТОР** *м.* — кинооператор (кинокартиналарны төшерүче).

**КИНОПЕРЕДВИ'ЖКА** *ж.* — күчмә кино.

**КИНОПЛЁНКА** *ж. мн.* нет — киноплёнка (киносъёмкалар төшерү плёнкасы).

**КИНОРЕЖИССЁР** *м.* — кинорежиссёр (кино өчен пьесалар кую белән җитәкчелек итүче режиссёр).

**КИНОСЕ'ТЬ** *ж.* — кинолар челтәре.

**КИНОСЪЁМКА** *ж.* — кинога төшереп алу, киносъёмка.

**КИНОТЕА'ТР** *м.* — кинотеатр, кино.

**КИНОТЕ'ХНИКА** *ж. мн.* нет — кинотехника (киноны җиһазлау һәм фильмнар кую техникасы).

**КИНОФА'БРИКА** *ж.* — кинофабрика (кинокартиналар эшләп чыгару предприятиесе).

**КИНОФИКА'ЦИЯ** *мн.* нет, *спец.* — к. кинофицировать.

**КИНОФИ'ЛЬМ** *м.* — кинофильм, кинокартина.

**КИНОФИЦИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.* — 1. кинофикацияләү, кинолар челтәре булдыру; *кинофицировать деревню* — авылны кинофикацияләү, авылларда кинолар челтәре булдыру; 2. кинокартиналар күрсәтү; *кинофицировать школы* — мәктәпләрдә кинокартиналар күрсәтү.

**КИНОФИЦИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. страд.* — 1. кинофикацияләнү; 2. кинокартиналар күрсәтелү.

**КИНО'ШКА** *ж. простореч. пренебр.* — кинотеатр.

**КИ'НУТЬ** *сов. разг.* — к. кидать.

**КИ'НУТЬСЯ** *сов. разг.* — ташлану, егылу; *кинуться в ноги кому-нибудь* — кемнең дә булса аягына егылу.

**КИО'СК** *м.* — киоск (газета, китап, куас, тәмәке, чәчәк кебек әйберләр сату будкасы).

**КИОСКЁР** *м.* — киоскта сату итүче.

**КИО'Т** *м. церк.* — киот (иконалар куя торган пыялалы ящик яки махсус шкаф).

**КИ'ПА** *ж.* — 1. төргәк, кип; 2. өем; *кипа вещей* — әйберләр өеме.

**КИПАРИ'С** *м. бот.* — кипарис (көньякта үсә торган мәңге яшел ылыслы агач).

**КИПАРИ'СНЫЙ, КИПАРИ'СОВЫЙ** — 1. кипарис...-ы; *кипарисное масло* — кипарис мае; 2. кипарис..., кипаристан ясалган; *кипарисовая ложка* — кипарис кашык.

**КИ'ПЕНЬ** *ж. мн* нет, *обл.* — 1. кайнар су; 2. ак күбек.

**КИПЕ'ТЬ** *несов.* — 1. кайнау; *самовар кипит* — самовар кайный; *вода кипит* — су кайный; 2. *перен.* кайнау, кайнап тору; *ключ кипит* — чишмә кайнап тора; *работа кипит* — эш кайнап тора; 3. ургылу, ташырга тору; *кипят желания* — теләкләр ургылалар, ташырга торалар. ◇ **Как в котле кипеть** — өзлексез, тынгысыз эштә яки мәшәкатьтә булу. **Слёзы кипят** *книж.* — күз яшьләре тамып чыгарга тора.

**КИПРЕ'Й** *м. бот.* — кырлыган (чәй урынына кулланыла торган үсемлек).

**КИПСЕ'Й** *м.*, **КИПСЕ'ЙКА** *ж. тип.* — кипсей (китап басу машинасында буяу ящигы).

**КИПУ'ЧЕСТЬ** *ж. мн.* нет — ярсучанлык, ашкынучанлык, дәртлелек.

**КИПУ'ЧИЙ** — 1. кайнап, күбекләнеп тора торган; *кипучий поток* — кайнап, күбекләнеп тора торган агым; 2. *перен.* ярсучан, ярсулы, ашкынулы, дәртле; *кипучий характер* — ашкынулы характер.

**КИПЯТИ'ЛКА** *ж. просторeч.* — 1. су кайнаткыч; 2. су кайнату бүлмәсе.

**КИПЯТИ'ЛЬНИК** *м.* — су кайнаткыч.

**КИПЯТИ'ЛЬНЫЙ** — кайнату...-ы, кайната торган; *кипятильный котёл* — кайнату казаны.

**КИПЯТИ'ТЬ** *несов.* — кайнату.

**КИПЯТИ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. *страд.* кайнатылу; *бельё кипятится* — кер кайнатыла; 2. *перен. разг.* кызу, ачулану, чәпчү; *не кипятись, говори спокойно* — кызма, тыныч кына сөйлә.

**КИПЯТО'К** *м. мн.* нет — 1. кайнар су; кайнап чыккан су, кайнаган су; *ошпарить кипятком* — кайнар су белән пешекләү (пешерү); 2. *перен. разг. фам.* кызу кеше, тиз кабынучан кеше, кабынып китүчән кеше, кызу канлы кеше.

**КИПЯЧЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — к. кипятить.

**КИПЯЧЁНЫЙ** — кайнаган; *кипячёная вода* — кайнаган су.

**КИРА'СА** *ж. воен. истор.* — кираса (күкрәккә һәм аркага киелә торган металл кием).

**КИРАСИ'Р** *м. воен. дореeол.* — кирасир (авыр кавалериянең кайбер частьларында хезмәт итүче гаскәри; парадка чыкканда кираса кигәнгә күрә шулай аталган).

**КИРАСИ'РСКИЙ** — кирасирлар...-ы; *кирасирский полк* — кирасирлар полкы.

**КИРГИ'З** *м.* — кыргыз.

**КИРГИ'ЗКА** *ж.* — кыргыз хатын-кызы.

**КИРГИ'ЗСКИЙ** — кыргыз...-ы; *киргизский язык* — кыргыз теле.

**КИРГИ'ЗЫ** *мн.* — кыргызлар, кыргыз халкы.

**КИ'РКА** *ж.* — кирка, лютераннар чиркәве.

**КИРКА'** *ж. тех.* — кирка, кәйлә.

**КИРКО'ВЫЙ** — кирка белән..., кәйлә белән...; *кирковая работа* — кирка белән эшләү.

**КИРПИ'Ч** *м.* — 1. кирпеч; 2. кирпечсыман әйбер.

**КИРПИ'ЧАТЫЙ** *обл.* — к. кирпичный 2.

**КИРПИ'ЧИК** *м.* — 1. кечкенә кирпеч; 2. *только мн.* шакмак (балалар уенчыгы шакмагы).

**КИРПИ'ЧИНА** *ж. просторeч.* — бер данә кирпеч.

**КИРПИЧИ'НА** *ж. просторeч.* — зур кирпеч.

**КИРПИ'ЧНИК** *м. спец.* — кирпечче, кирпеч сугучы.

**КИРПИ'ЧНЫЙ** — 1. кирпеч...-ы; *кирпичное производство* — кирпеч производствосы; 2. кирпеч (тән ясалган); *кирпичная стена* — кирпеч стена. ◇ **Кирпичный чай** — такта чәй.

**КИ'СА** *ж. разг. фам.* — песи, мәче.

**КИСА'** *ж. обл.* — янчык (авызы бөрмәле янчык яки капчык).

**КИСЕ'ЙКА** *ж. разг.* — к. кисея.

**КИСЕ'ЙНЫЙ** — кисея...-; *кисейное производство* — кисея производствосы; 2. кисея (дән тегелгән); *кисейное платье* — кисея күлмәк.

**КИСЕЛЕОБРА'ЗНЫЙ** — кесәлсыман.

**КИСЕ'ЛЬ** *м.* — 1. кесәл; 2. *перен. просторeч.* булдыксыз кеше, җебегән кеше. ◇ **Дать киселя** *кому вульг.* — тез белән артына тибү. **Десятая или седьмая вода на киселе** *разг. фам. шутл.* — күпердән чыкканда кучәр башлары эләккән; чыбык очы (бик ерак кардәшләр турында).

**КИСЕ'ЛЬНЫЙ** — кесәл...-ы; *кисельная масса* — кесәл массасы.

**КИСЕ'Т** *м.* — янчык, тәмәке янчыгы.

**КИСЕЯ'** *ж. мн.* нет — кисея (үтә күренмәле юка тукыма).

**КИ'СКА** *ж.* — к. киса.

**КИС-КИС** *межд. разг.* — пес-пес (мәче чакыру ымлыгы).

**КИ'СЛЕНЬКИЙ** *разг.* — әчкелтем.

**КИСЛЕ'ТЬ** *несов. разг.* — әчү, әчеләнү.

**КИСЛИ'НКА** *ж. просторeч.*: с **кислинкой** — әчкелтем; *яблоко с кислинкой* — әчкелтем алма.

**КИСЛИ'ТЬ** *несов. разг.* — 1. әчетү, әчеләндерү; 2. әчкелтем тәм килү; *яблоко немножко кислит* — алмадан бераз әчкелтем тәм килә.

**КИСЛОВА'ТЫЙ** — әчкелтем, әчкелт.

**КИСЛО'ВКА** *ж. тех.* — кислота белән эшкәртү.

**КИСЛО'ВЩИК** *м. спец.* — кислота белән эшкәртүче.

**КИСЛОРО'Д** *м. мн.* нет, *хим.* — кислород.

**КИСЛОРО'ДИСТЫЙ, КИСЛОРО'ДНЫЙ** — кислородлы; *кислородные соединения* — кислородлы кушылмалар.

**КИСЛОСЛА'ДКИЙ** — әчкелтем-төчкелтем.

**КИСЛОТА'** *ж.* — 1. *хим.* кислота; *серная кислота* — сульфат кислотасы; 2. *разг.* әчелек, әче нәрсә.

**КИСЛО'ТНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *хим.* — кислоталылык дәрәҗәсе.

**КИСЛО'ТНЫЙ** — кислоталы; *кислотные соединения* — кислоталы кушылмалар.

**КИСЛОТОУПО'РНЫЙ** *хим. тех.* — кислотага чыдам, кислота тәэсиренә бирелмәүчән.

**КИ'СЛЫЙ** — 1. әче; *кислое яблоко* — әче алма; 2. әчегән, әчеп бозылган; *кислая картошка* — әчегән бәрәңге; 3. *перен.* төшенке, борчылулы; *кислое настроение* — төшенке күңел; (*о лице*) чытык, сытык; *кислое лицо* — сытык чырай; (*о слове*) әче; *сказать несколько кислых слов* — берничә әче сүз әйтү; 4. *хим. тех.* кислоталы; *кислые растворы* — кислоталы эремәләр. ◇ **Кислое молоко** — катык.

**КИСЛЯ'И** *м. просторeч. пренебр.* — җебегән, сүлпән, зарланучан, сыкранучан (кеше).

**КИСЛЯ'ТИНА** *ж. разг. фам.* — 1. әче нәрсә; 2. *перен.* к. кисляй.

**КИ'СНУТЬ** *несов.* — 1. әчү; *молоко киснет* — сөт әчи; 2. *перен.* боегу, кайгыру, боегып тору, кайгырып тору; *нечего киснуть, надо приняться за работу* — боегып торыр урын юк (боегып торасы юк), эшкә тотынырга кирәк; 3. *переч. разг. фам. неодобр.* мүкләнеп яту.

**КИСТА'** *ж. мед.*—сулы шеш, киста (сыекча белән тулган шеш).

**КИСТЕ'НЬ** *м.* — кистән (чукмарлы таяк, борынгы сугыш коралы). ◇ **Ходить с кистенём** *нар.-поэт.*—талау белән шөгыльләнү.

**КИСТОВЯ'З** *м. спец.* — пумала ясаучы.

**КИ'СТОЧКА** *ж.* — 1. кечкенә пумала, кисточка; 2. чук, чачак; *шапочка с кисточкой* — чуклы бүрек; 3. тәлгәш; *кисточка винограда* — виноград тәлгәше.

**КИСТЬ** *ж.* — 1. пумала (буяучы пумаласы); 2. чук, чачак; *портьеры с кистями* — чачаклы пәрдәләр; 3. тәлгәш, тәрмәч; *кисти винограда* — виноград тәлгәшләре; 4. кул чугы, кул бармаклыгы (кулның беләзектән түбәнге өлеше).

**КИТ** *м.* — кит (диңгездә яши торган имезүче хайван).

**КИТА'ЕЦ** *м.* — кытай.

**КИТАИ'СТ** *м.* — китаист, синолог (кытай телен, әдәбиятын, тарихын һәм культурасын белүче).

**КИТА'ЙКА** *ж. мн.* нет, *истор.* — китайка (мамык тукыманың бер төре).

**КИТА'ЙСКИЙ** — кытай...-ы; *китайский язык* — кытай теле.

**КИТА'ЙЦЫ** *мн.* (*ед.* китаец) — кытайлар, кытай халкы.

**КИТАЯ'НКА** *ж.* — кытай хатын-кызы.

**КИ'ТЕЛЬ** *м.* — китель (утырма якалы җәйге куртка); морской китель — диңгезчеләр кителе.

**КИТОБО'ЙНЫЙ** *спец.* — кит аулау...-ы; *китобойное судно* — кит аулау судносы.

**КИТО'ВЫЙ** — кит...-ы; *китовый ус* — кит мыегы.

**КИТОЛО'В** *м.* — кит аулаучы.

**КИТОЛО'ВНЫЙ** — кит аулау...-ы; *китоловный промысел* — кит аулау промыселы.

**КИТОЛО'ВСТВО** *ср. мн.* нет — кит аулаучылык, кит аулау кәсебе.

**КИ'ЧИТЬСЯ** *несов.* — масаю, мактану, шапырыну, борын күтәрү, эреләнү, тәкәбберләнү.

**КИ'ЧКА** *ж. обл.*— 1. кичка (кияүдәге хатын-кызларның бәйрәмдә кия торган баш киеме); 2. пароходның борыны.

**КИЧЛИ'ВОСТЬ** *ж. мн.* нет — мактанчыклык, тәкәбберлек.

**КИЧЛИ'ВЫЙ** — масаючан, мактанчык, тәкәббер, эреләнүчән.

**КИШ** *межд.* — көш-көш (кош куу яки куркыту ымлыгы).

**КИШЕ'ТЬ** *несов.* — 1. (*шевелиться, копошиться*) мыжлап тору, гөж килеп тору; 2. тулып яту; *тундра кишит комарами* — тундрада озынборыннар тулып ята. ◇ **Кишмя кишеть** *разг.* —к. кишеть.

**КИШЕ'ЧНИК** *м. анат.* — эчәкләр.

**КИШЕ'ЧНЫЙ** — 1. эчәк...-ы; *кишечные заболевания* — эчәк авырулары; 2. эчәк (тән ясалган); *кишечные струны* — эчәк кыллар.

**КИШКА'** *ж.* — 1. эчәк; *прямая кишка* — туры эчәк; 2. насос эчәгесе. ◇ **Кишка тонка или слаба или кишка не выдержит** *вульг. пренебр.* — көчең җитмәс, кулыңнан килмәс. **Надорвать кишки (со смеху)** *разг. фам.* — эч катканчы көлү. **Выпустить кишки** *простореч.* — үтерү. **Вымотать (все) кишки** *простореч.* — азаплап бетерү, теңкәсенә тию.

**КИШКООБРА'ЗНЫЙ** —эчәксыман.

**КИШЛА'К** *м.* — кышлак (авыл).

**КИШЛА'ЧНЫЙ** — кышлак...-ы; *кишлачный совет* — кышлак советы.

**КИШМИ'Ш** *м. мн.* нет— кишмиш (төшсез вак виноград һәм аннан хәзерләнгән йөзем).

**КИШМЯ'** *нареч.*: **кишмя кишеть** — к. кишеть.

**КЛАВИАТУ'РА** *м. спец.* — клавиатура (клавишлы музыкаль инструментларда һәм кайбер механизмнарда, мәсәлән, язу машинасында, клавишлар җыелмасы).

**КЛАВИКО'РДЫ** *только мн. муз.* — клавикорд (фортепьяноның дүртпочмак формасындагы элекке төре).

**КЛА'ВИШ** *м.* — клавиш (музыка коралы, язу машинкасы кебек механизмнарда рычагны хәрәкәткә китерү өчен бармаклар белән баса торган төймәләр, пластинкалар).

**КЛА'ВИШНЫЙ** — клавишлы; *клавишный инструмент* — клавишлы инструмент.

**КЛАД** *м.* — хәзинә (җиргә күмелгән кыйммәтле әйбер, акча).

**КЛА'ДБИЩЕ** *ср.* — каберлек, зират.

**КЛА'ДБИЩЕНСКИЙ** — каберлек...-ы; зират...-ы; *кладбищенский сторож* — каберлек сакчысы.

**КЛА'ДЕЗЬ** *м. церк. книж. поэт-устар.* — кое. ◇ **Кладезь премудрости** *шутл.* — акыл капчыгы (киң белемле кеше турында).

**КЛА'ДЕНЕЦ** *м.*: **меч-кладенец** — хикмәтле кылыч, серле кылыч (әкиятләрдә).

**КЛА'ДЕНЫЙ** *спец. обл.* — печелгән, печтерелгән (терлек).

**КЛА'ДИ** *мн.* (*ед.* кладь) *обл.* — басма (суны яки баткаклыкны үтеп чыгу өчен аяк астына салынган бүрәнә, такта, таш, кирпечләр).

**КЛА'ДКА** *ж.* — 1. салу; *кладка стен* — стена салу; 2. өю; *кладка дров* — утын өю; 3. йомырка салу; 4. *обл.* печү, печтерү; 5. корылма; *эту часть кладки надо разобрать* — корылманың бу өлешен сүтәргә кирәк.

**КЛА'ДКИ** *мн.* (*ед.* кладка) *обл.* — басма; *перейдём через ручей по кладкам* — елга аркылы басмадан чыгыйк.

**КЛАДОВА'Я** *ж.* — кладовой (кирәк-яракларны саклау урыны).

**КЛАДО'ВКА** *ж. разг.*—кечкенә кладовой.

**КЛАДОВЩИ'К** *м. спец.* — кладовщик, кладовой мөдире.

**КЛА'ДЧИК** *м. спец.* — салучы, түшәүче, өючe (эшче).

**КЛАДЬ** *ж.* — 1. *собир.* йөк; 2. *обл.* эскерт, иген эскерте; 3. *обл.* өрлек, матча; 4. к. кладки.

**КЛА'КА** *ж. мн.* нет, *собир. театр.* — 1. театр клакёрлары; 2. *перен. пренебр.* мактаучылар, олылаучылар төркеме.

**КЛАКЁР** *м. театр.* — клакёр (буржуаз җәмгыятьтә: пьеса яки артистларның уйнавы уңышлы чыкты дигән тәэсир тудыру өчен ялланып кул чабучы).

**КЛАКСО'Н** *м. тех.* — клаксон (автомобильдә, тракторда механик сигнал гудогы).

**КЛАН** *м. истор.* — клан (борынгы заманда шотландиялеләрдә һәм ирландиялеләрдә ыруг общинасы, ыругдагы бер башлыкка буйсынган кардәшләр группасы).

**КЛА'НЯТЬСЯ** *несов.* — 1. баш ию, котлау, сәламләү (баш иеп); 2. сәлам әйтү, сәлам тапшыру; *кланяйтесь ему от меня* — аңа миннән сәлам әйтегез (тапшырыгыз); 3. ялыну, ялварып сорау; *не стану я перед ним кланяться* — мин аңа ялынып тормам; 4. *(приносить в дар) устар.* бүләк итеп бирү, бүләкләү. ◇ **Перестать кланяться или не кланяться** — танышлыкны өзү. **Честь имею кланяться** *дорев.* — сау булыгыз, хушыгыз.

**КЛА'ПАН** *м.* — 1. клапан (а. *тех.* механизмда берәр тишекне ача яки каплый торган каплавыч; б. *анат.* йөрәкнең канны кирегә таба хәрәкәт иттерми торган кисәге); 2. *(у кармана)* каплавыч, япкыч.

**КЛАРНЕ'Т** *м. муз.* — кларнет (агачтан ясалган курайсыман музыка коралы).

**КЛАРНЕТИ'СТ** *м.* — кларнетчы, кларнетта уйнаучы, кларнетист.

**КЛАСС** *м.* — 1. сыйныф; *рабочий класс* — эшчеләр сыйныфы; 2. класс; *ученик первого класса* — беренче класс укучысы; 3. класс, төркем; *класс млекопитающих* — имезүчеләр классы (төркеме); 4. дәрәҗә; *драгоценные камни первого класса* — беренче дәрәҗәдәге кыйммәтле ташлар; 5. класс; *каюта первого класса* — беренче класс каютасы.

**КЛА'ССИК** *м.* — классик (1. гомумхалык тарафыннан танылган атаклы язучы, музыкант, художник, галим; 2. сәнгатьтә классицизм тарафдары; 3. борынгы грек яки рим язучысы; 4. классик белем алган, классик телләрне яхшы белүче кеше; 5. борынгы грек һәм латин телләре яки әдәбияты галиме, белгече; 6. *разг.* классик филологияне өйрәнүче студент).

**КЛА'ССИКА** *ж. мн.* нет — классика, классик әсәрләр.

**КЛАССИФИКА'ТОР** *м.* — 1. классификатор, классификацияләүче, классификация белгече; 2. *горн.* классификатор (бөртекләренең эрелекләренә карап руданы сортларга аера торган прибор).

**КЛАССИФИКА'ЦИЯ** *ж.* — классификация (1. классларга, бүлекләргә, бүлекчәләргә бүлү, аеру; 2. классларга, бүлекләргә, бүлекчәләргә бүлү, аеру системасы).

**КЛАССИФИЦИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. книж.* — классификацияләү, классларга, бүлекләргә, бүлекчәләргә, төркемнәргә бүлү, аеру.

**КЛАССИФИЦИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. страд. книж.* — классификацияләнү, классларга, бүлекләргә, бүлекчәләргә, төркемнәргә бүленү, аерылу.

**КЛАССИЦИ'ЗМ** *м. мн.* нет — классицизм (1. белем алуның антик (классик) телләрне һәм әдәбиятны өйрәнүгә нигезләнгән системасы; 2. сәнгатьтә, әдәбиятта антик үрнәкләргә ияреп эш итүгә нигезләнгән юнәлеш).

**КЛАССИ'ЧЕСКИ** *нареч. разг.* — шәп, бик шәп, менә дигән, искиткеч яхшы; *докладчик классически отвечал оппонентам* — докладчы оппонентларга искиткеч яхшы җавап бирде.

**КЛАССИ'ЧЕСКИЙ** — 1. классик; классиклар тарафыннан иҗат ителгән; *классическая музыка* — классик музыка; 2. типик, характерлы; *классический пример рассеянности* — таркаулыкның характерлы мисалы (үрнәге); 3. антик, классик (борынгы грек-рим культурасына караган); *классические языки* — классик телләр, антик телләр.

**КЛА'ССНЫЙ** — 1. класс...-ы; *классная доска* — класс тактасы; 2. бик яхшы, үрнәк булырлык; *классная игра* — бик яхшы уйнау, үрнәк булырлык уйнау. ◇ **Классный вагон** — класслы вагон.

**КЛА'ССОВО** *нареч.* — сыйнфый, сыйнфый яктан; *классово чуждый* — сыйнфый яктан чит.

**КЛА'ССОВЫЙ** — сыйнфый; *классовая борьба* — сыйнфый көрәш.

**КЛАСТЬ** *несов.* — 1. салу; *класть платок в карман* — яулыкны кесәгә салу; 2. урнаштыру, салу; *класть больного в больницу* — авыруны больницага салу; 3. басу; *класть печать* — печать басу; 4. чыгару, салу; *класть печь* — мич чыгару; 5. кую; *класть много силы на работу* — эшкә күп көч кую; 6. ягу, буяу; *класть пудру* — пудра ягу; 7. *обл. спец. (кастрировать животных)* печү. ◇ **Класть начало** — башлап җибәрү. **Класть в рот** *перен.* — чәйнәп бирү (җентекләп аңлату). **Класть оружие** *книж. устар.* — корал ташлау, бирелү, үзенең җиңелгәнлеген тану. **Класть в основу** *книж.* — нигез итеп алу.

**КЛЁВ** *м. мн.* нет — чиртү, кабу, эләгү; *сегодня хороший клёв* — бүген балык яхшы чиртә, каба.

**КЛЕВА'ТЬ** *несов.* — 1. ашау, чукып ашау, чүпләү; *куры не клюют этого корма* — тавыклар бу азыкны ашамыйлар; 2. чуку; *петух клюёт щенка* — әтәч көчекне чукый; 3. чиртү, кабу; *сегодня рыба не клюёт* — бүген балык чиртми. ◇ **Ну как, клюёт?** *разг. шутл.* — ну ничек, чиртәме? (эшләр уңайга барамы?) **Клевать носом** *разг.* — черем итү, утырган килеш йокымсырау.

**КЛЕВА'ТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. чуку; *ай,*

*как она больно клюётся!* — ай, ничек авырттырып чукый ул; 2. чукышу, сугышу; *петушки ожесточённо клюются* — әтәчләр бик каты сугышалар.

**КЛЕ'ВЕР** *м. мн.* нет, *бот.* — тукранбаш, клевер.

**КЛЕ'ВЕРНЫЙ** — клевер...-ы; *клеверное поле* — клевер кыры.

**КЛЕВЕТА'** *ж.* — яла, ялган.

**КЛЕВЕТА'ТЬ** *несов.* — яла ягу, ялган тарату, ялган хәбәр тарату; *буржуазная пресса клевещет на нас, завидуя нашим достижениям* — буржуаз матбугат, безнең уңышларыбыздан көнләшеп, безнең турыда ялган хәбәр тарата.

**КЛЕВЕТНИ'К** *м.*, **КЛЕВЕТНИ'ЦА** *ж.* — яла ягучы, ялганчы, ялган хәбәр таратучы.

**КЛЕВЕТНИ'ЧЕСКИЙ** — ялган, йөзгә кара яга торган; *клеветнические слухи* — ялган хәбәрләр, йөзгә кара яга торган хәбәрләр.

**КЛЕВО'К** *м. разг.* — чукып алу.

**КЛЕВРЕ'Т** *м.* — иярчен (берәр начар эштә); *клевреты буржуазии* — буржуазиянең иярченнәре.

**КЛЕЕВА'Р** *м.* — җилем кайнатучы, җилем ясаучы (эшче).

**КЛЕЕВАРЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — җилем кайнату, җилем ясау.

**КЛЕЕВА'РЕННЫЙ** — җилем кайнату..-ы; *клееваренный завод* — җилем кайнату заводы.

**КЛЕЕВА'РНЯ** *ж. спец.* — җилем кайнату бинасы.

**КЛЕЕВА'Я** — ябыштыру мастерское.

**КЛЕЕВО'Й** — 1. җилем...-ы; *клеевой запах* — җилем исе; 2. җилемле; *клеевая краска* — җилемле буяу.

**КЛЕЁНКА** *ж.* — клеёнка.

**КЛЕЁНОЧНЫЙ** — клеёнка...-ы; *клеёночная мастерская* — клеёнка мастерское.

**КЛЕЁНЧАТЫЙ** — клеёнка(дан ясалган), клеёнка белән тышланган; *клеёнчатый портфель* — клеёнка портфель; *клеёнчатый диван* — клеёнка белән тышланган диван.

**КЛЕЁНЫЙ** — җилемле, җилемләнгән; *клеёная бумага* — җилемле кәгазь.

**КЛЕИ'ЛЬНЫЙ** — ябыштыру...-ы; *клеильная мастерская* — ябыштыру мастерское.

**КЛЕИ'ЛЬЩИК** *м.*, **КЛЕИ'ЛЬЩИЦА** *ж.* — ябыштыручы (эшче).

**КЛЕИ'ТЬ** *несов.* — ябыштырып ясау, җилем белән ябыштырып ясау, ябыштыру, җилемләп ябыштыру.

**КЛЕИ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. ябыштырылу, җилемләнү, ябыштырып ясалу; 2. *простореч.* ябышу; *от смолы пальцы клеятся* — сумаладан бармаклар ябыша. ◇ **Дело плохо клеится или дело не клеится** *разг. фам.* — эш барып чыкмый, эш начар бара, эш пешми.

**КЛЕЙ** *м. мн.* нет — җилем.

**КЛЕ'ЙКА** *ж. мн.* нет — җилемләү, җилем белән ябыштыру.

**КЛЕ'ЙКИЙ** — ябышучан, ябышкак.

**КЛЕЙКОВИ'НА** *ж. мн.* нет, *биол.* — клейковина, җилемчә (ашлык бөртегендә була торган аксым матдәсе).

**КЛЕ'ЙКОСТЬ** *ж. мн.* нет — ябышучанлык, ябышкаклык.

**КЛЕЙМЕ'НИЕ** *ср. спец.* — к. клеймление.

**КЛЕЙМЁНЫЙ** — кләймәле, тамгалы, кләймәләнгән, кләймә сугылган, тамгаланган, тамга салынган; *клеймёный товар* — кләймәле товар, кләймә сугылган товар; *клеймёный скот* — тамгалы терлек, тамга салынган терлек.

**КЛЕЙМИ'ТЬ** *несов.* — 1. кләймәләү, кләймә сугу; *клеймить товар* — товарга кләймә сугу; 2. тамгалау, тамга салу; *клеймить скот* — терлеккә тамга салу; 3. *перен.* фаш итү, хур итү, гаебен ачу; *клеймить трусов* — куркакларны фаш итү, хур итү.

**КЛЕЙМЛЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — к. клеймить 1,2.

**КЛЕЙМО'** *ср.* — 1. *(на товаре)* кләймә; *(на коже)* тамга; 2. *(орудие клеймления)* кләймә; 3. *перен.* эз; *клеймо несчастья* — бәхетсезлек эзе; 4. *перен.* тап; *клеймо позора* — хурлык табы.

**КЛЕЙМО'ВЩИК** *м. спец.* — кләймә сугучы.

**КЛЕ'ЙСТЕР** *м. мн.* нет — клейстер (крахмалдан яки оннан ясалган җилем).

**КЛЁКОТ** *м.* — коркылдау (каракош яки башка эре кошларның кычкыруы).

**КЛЕКОТА'ТЬ** *несов.*, **КЛЕКТА'ТЬ** *несов. обл.* — коркылдау (каракош һәм башка эре кошлар кычкыруы).

**КЛЕ'ММА** *ж. тех.* — клемма, кыстыргыч.

**КЛЁН** *м. бот.* — өрәңге, чаган.

**КЛЁНОВЫЙ** — 1. өрәңге...-ы; *клёновый лист* — өрәңге яфрагы; 2. өрәңге(дән ясалган); *клёновая ложка* — өрәңге кашык.

**КЛЕПА'ЛО** *ср.* — 1. *тех.* клёпка чүкече, клёпка кага торган чүкеч; 2. *истор.* чаң тактасы.

**КЛЕПА'ЛЬНЫЙ** *тех.* — клёпкалау...-ы; *клепальная машина* — клёпкалау машинасы.

**КЛЕПА'ЛЬЩИК** *м.* — клёпкалаучы (эшче).

**КЛЁПАНЫЙ** — клёпкалап ясалган.

**КЛЁПАНЬ** *ж. мн.* нет, *тех.* — тимер кыршау.

**КЛЕПА'ТЬ** I *несов. тех.* — клёпкалау, чүкеп беркетү (металл әйберләрне).

**КЛЕПА'ТЬ** II *несов. простореч.* — яла ягу, яла тарату, ялган хәбәрләр тарату (берәр кеше турында).

**КЛЁПКА** *ж.* — 1. к. клепать I; 2. кисмәк тактасы, мичкә тактасы, клёпка.

**КЛЁПОЧНЫЙ** — клёпка ...-ы; клёпка ясау...-ы; *клёпочный станок* — клёпка ясау станогы.

**КЛЕПТОМА'Н** *м.*, **КЛЕПТОМА'НКА** *ж. мед.* — клептоман, клептоманка, клептомания белән авыручы.

**КЛЕПТОМА'НИЯ** *ж. мн.* нет, *мед.* — клептомания (урлашмыйча, каракланмыйча тора алмаудан гыйбарәт булган психик авыру).

**КЛЕРИКА'Л** *м. полит.*— клерикал, клерикализм тарафдары.
**КЛЕРИКАЛИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *полит* — клерикализм (буржуаз илләрдә илнең политик һәм культура тормышын чиркәү оешмалары җитәкчелегенә бирергә омтыла торган реакцион политик агым).
**КЛЕРИКА'ЛЬНЫЙ** — клерикаль; *клерикальная партия* — клерикаль партия.
**КЛЕРК** *м.*— контора хезмәтчесе (Көнбатыш Европада).
**КЛЕРОВА'ЛЬНЫЙ** *тех.* — чистарту...-ы; *клеровальный котёл*— (май, шикәр һ. б. ны) чистарту казаны.
**КЛЕРОВА'ТЬ** *несов. тех.*— чистарту, сафлау (шикәрне, майны һ. б.).
**КЛЕСТ** *м. зоол.*— чукыр (кош).
**КЛЕСТО'ВКА** *ж. зоол.*— ана чукыр.
**КЛЁСТОВЫЙ** — чукыр ...-ы; *клёстовые яйца* — чукыр йомыркалары.
**КЛЕ'ТКА** *ж.*— 1. читлек; *птица сидит в клетке* — кош читлектә утыра; 2. шакмак; *на шахматной доске черные и белые клетки* — шахмат тактасында кара һәм ак шакмаклар; 3. челтәр; *сложить брёвна в клетку* — бүрәнәләрне челтәрләп өю; 4. *биол.* күзәнәк; *нервная клетка* — нерв күзәнәге. ◇ **В клетку или клетками** — шакмаклы; *материя в клетку* — шакмаклы материя. **Грудная клетка** *анат.*— күкрәк читлеге.
**КЛЕТКОВИ'НА** *ж. мн.* нет, *бот.* — к. клетчатка.
**КЛЕ'ТОЧКА** *ж.*— к. клетка 1, 2, 4.
**КЛЕ'ТОЧНЫЙ** — 1. читлек...-ы; *клеточная мастерская* — читлек мастерское; 2. күзәнәк...-ы; *клеточная протоплазма*— күзәнәк протоплазмасы.
**КЛЕТУ'ШКА** *ж. простореч.* — 1. кечкенә келәт; 2. кечкенә бүлмә.
**КЛЕТЧА'ТКА** *ж.* — клетчатка (1. үсемлек күзәнәкләренең тышчасы составында була торган матдә; 2. клетчатканы эшкәртү нәтиҗәсендә барлыкка килә торган җепсел матдә).
**КЛЕ'ТЧАТЫЙ** I — шакмаклы, шакмак бизәкле; *клётчатое пальто* — шакмаклы пальто.
**КЛЕ'ТЧАТЫЙ** II — күзәнәкле; *клетчатое строение растительной ткани* — үсемлек тканенең күзәнәкле төзелеше.
**КЛЕТЬ** *ж. обл.* — келәт
**КЛЁЦКИ** *мн.* (*ед.* клёцка) — чумар, умач.
**КЛЁШ** *м.*— клёш (түбәнгә таба киңәеп киткән балак, чабу).
**КЛЕШНЕВИ'ДНЫЙ, КЛЕШНЕОБРА'ЗНЫЙ** *книжн. спец.*— камыт агачысыман.
**КЛЕШНИ'** *мн.* (*ед.* клешня) — камыт агачы.
**КЛЕШНЯ'** *ж.* — 1. кыскыч (кысланың кыскычы); 2. *спец. только мн.* камыт агачы.
**КЛЕЩ** *ж. зоол.*— урман бете, талпан.
**КЛЕЩЕВИ'НА** *ж. мн.* нет, *бот.* — кәнә үләне, кастор үләне.
**КЛЕЩЕВИ'ННЫЙ** — кәнә үләне ...-ы; *клещевинное масло* — кәнә үләне мае.
**КЛЕ'ЩИ'** *ед.* нет — keләшчә, каргаборын.
**КЛЕЯ'НКА** *ж. спец.*— җилем эретү савыты.
**КЛИ'ВЕР** *м. мор.* — өчпочмаклы кыйгач җилкән.
**КЛИЕ'НТ** *м.*, **КЛИЕ'НТКА** *ж.* — клиент (1. парикмахерга, адвокатка һ. б. эш белән килүче; 2. һәрвакыт заказ бирүче, сатып алучы).
**КЛИЕНТУ'РА** *ж. собир.* — клиентлар.
**КЛИЕНТУ'РНЫЙ** — клиентлар...-ы; *клиентурные поручения* — клиентлар кушкан эшләр.
**КЛИ'ЗМА** *ж. мед.*— 1. клизма (арт юлдан сыекча җибәреп эчәкләрне чистарту, арындыру; 2. шуның приборы).
**КЛИК** *м. книж.-поэт.*— кычкыру, дәшү, эндәшү, чакыру.
**КЛИ'КА** *ж. пренебр.*— клика, өер, шайка (явыз максат белән оешкан кешеләр төркеме).
**КЛИ'КАТЬ** *несов. простореч.*— 1. *(о гусях, лебедях)* кыйгаклау, кыңгылдау; 2. *(громко звать)* кычкырып чакыру, кычкырып дәшү; 3. атау; *его Ванькой кличут* — аны Ванька дип атыйлар (аның исеме Ванька; ул Ванька исемле); 4. *(кричать в припадке истерики)* акыру, каты кычкыру.
**КЛИ'КНУТЬ** *однокр.*— чакырып алу, чакырып китерү. ◇ **Кликнуть клич** *ритор.*— өндәп мөрәҗәгать итү (халыкка, җәмгыятькә).
**КЛИКУ'Н** *м. обл.*— 1. кыйгаклаучы, каты кычкыручы (каз яки аккош); 2. ерткычны алдап тозакка китерер өчен бәйләп куелган сарык бәрәне яки дуңгыз баласы.
**КЛИКУ'ША** *ж.* и *м.* — 1. *ж.* бума авырулы хатын-кыз; 2. *перен. м.* и *ж.* тотнаксыз, тотрыксыз, дуамал политикан.
**КЛИКУ'ШЕСТВО** *ср.*— 1. хатын-кызларда бума авыруы; 2. *перен. публиц. презрит.* тотнаксыз политиканлык, дуамал политиканлык.
**КЛИМАКТЕ'РИЙ** *м. мн.* нет, *мед.*— климактерий (хатыннарның 45—54 яшьләр арасында күрем күрүдән тукталу чоры).
**КЛИМАКТЕРИ'ЧЕСКИЙ** *мед.* —климактерик; *климактерический период* — климактерик чор.
**КЛИ'МАТ** *м.*— климат (билгеле бер урынга хас булган метеорологик шартлар).
**КЛИМАТИЗИ'РОВАТЬСЯ** *несов. книж.*— 1. климат шартларына күнегү, климат шартларына җайлану; 2. тормыш шартларына җайлану.
**КЛИМАТИ'ЧЕСКИЙ** — климат...-ы; *климатические условия* — климат шартлары.
**КЛИМАТОЛОГИ'ЧЕСКИЙ** — климатологик; *климатологические наблюдения* — климатологик күзәтүләр.
**КЛИМАТОЛО'ГИЯ** *ж. мн.* нет — климатология (метеорологиянең климатларны һәм аларның органик тормыш өчен әһәмиятен өйрәнү бүлеге).
**КЛИН** *м.* (*мн.* клинья) — 1. чөй; *дубовый клин* — имән чөй; 2. ялгау, чөйсыман ялгау; *вшить клин* — ялгау кертеп тегү;

3. *с.-х.* басу; *яровой клин* — сабан ашлык басуы. ◇ **Дело клином сошлось** *разг.* — көймә комга утырды.

**КЛИ'НИКА** *ж. мед.* — клиника (бер үк вакытта студентлар практика үтә торган һәм фәнни тикшеренүләр алып барыла торган дәвалау учреждениесе).

**КЛИНИЦИ'СТ** *м.* — клиницист (клиникада дәвалау эшләре алып бару белән бергә фәнни күзәтүләр һәм тикшеренүләр дә алып баручы врач).

**КЛИНИ'ЧЕСКИЙ** *мед.* — клиника ...-ы; *клиническое здание* — клиника бинасы. ◇ **Клинический больной** — клиникада ятып дәваланучы авыру.

**КЛИ'НКЕР** *м. тех.* — клинкер (утка чыдам һәм су үткәрми торган кирпеч).

**КЛИНКЕРОВА'ТЬ** *несов. тех.* — клинкер сугу.

**КЛИНОВИ'ДНЫЙ** — чөйсыман.

**КЛИНО'К** *м.* — 1. клинок (кылычның, пычакның һ. б. кисә торган өлеше); 2. *обл.* кечкенә чөй.

**КЛИНОЛИ'СТНЫЙ** *бот.* — чөйсыман яфраклы.

**КЛИНООБРА'ЗНЫЙ** — чөйсыман.

**КЛИНОПИ'СНЫЙ** *филол.* — чөй язулы; *клинописный текст* — чөй язулы текст.

**КЛИ'НОПИСЬ** *ж. филол.* — 1. чөй язу (хәрефләре чөйсыман сызыклардан торган борынгы язу); 2. чөй язулы текст.

**КЛИ'ПЕР** *м. мор.* — клипер (тиз йөрешле өч мачталы җилкәнле корабль).

**КЛИ'РОС** *м. церк.* — клирос (чиркәүдә җырлаучылар өчен биек урын).

**КЛИ'СТИР** *м.* — к. клизма.

**КЛИЧ** *м. ритор.* — кычкырып чакыру, өндәү.

**КЛИ'ЧКА** *ж.* — 1. *(прозвище)* кушамат; 2. *(имя домашнего животного)* исем.

**КЛИШЕ'** *ср. нескл. тип.* — 1. клише (типографиядә басу өчен металлга, ташка, агачка төшерелгән рәсем); 2. *перен. книж.* күп чәйнәлгән фикер, гадиләшеп беткән фикер.

**КЛОА'КА** *ж.* — 1. *истор.* клоака (шакшы су агызу өчен җир асты каналы); 2. пычрак урын, шакшы урын; 3. *перен.* бозык җәмгыять, бозык мохит (среда); 4. *зоол.* арт юл (амфибийларда, кошларда).

**КЛОБУ'К** *м. церк.* — монах бүреге, монах калпагы.

**КЛОЗЕ'Т** *м. разг.* — бәдрәф.

**КЛОК** *м.* (*мн.* клочья и клоки) — 1. тотам, бер уч; *клок шерсти* — бер тотам йон; 2. кисәк, кыйпык; *огромная туча разорвалась на мелкие клочья* — бик зур болыт вак кисәкләргә аерылды.

**КЛО'КОТ** *м. мн.* нет — 1. *(о воде)* шаулап кайнау, ургылып кайнау, быкырдау; 2. *(о звуках в груди)* хырылдау, гырылдау.

**КЛОКОТА'ТЬ** *несов.* — 1. шаулап кайнау, ургылып кайнау, быкырдау; *вода в котле клокотала* — казанда су шаулап кайный иде; 2. *(о звуках в груди)* хырылдау, гырылдау; 3. *перен. книж.* ярсу, ярсып тору, кайнап тору; *всё в нём клокотало от гнева* — ачуыннан ул тәмам ярсыган иде.

**КЛОКТА'ТЬ** *несов. обл.* — к. клохтать.

**КЛОНИ'ТЬ** *несов.* — 1. ию, бөгү, кырынайту, кыйшайту, авыштыру; *ветер клонит верхушки деревьев* — җил агач башларын ия; *лодку клонит на бок* — көймәне бер якка кырынайта; 2. *перен.* тарту, юнәлдерү, алып бару; *клонить дело к разрыву* — эшне өзүгә таба алып бару. ◇ **Меня ко сну клонит** — минем йоклыйсым килә, мин йокымсырап торам. **С первых же слов я понял, к чему он клонит** — беренче сүзләреннән үк мин аның тел төбе кая барганлыгын аңладым. **Я не мог понять, к чему он клонит** — аның тел төбе кая барганын мин аңлый алмадым; аның кая таба тартканын мин аңлый алмадым.

**КЛОНИ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. иелү, бөгелү; *дерево клонится к земле* — агач җиргә бөгелә; 2. якынлашу, якынлашып килү, авышу; *день клонится к вечеру* — көн кичкә авыша; *дело клонится к развязке* — эш чишелүгә якынлашып килә; эш чишелүгә таба бара; 3. *перен. книж.* кайтып калу; *мое мнение (предложение) клонится к следующему...* — минем фикерем (тәкъдимем) түбәндәгегә кайтып кала...

**КЛОП** *м.* — 1. кандала, кибәк; 2. *разг. фам. шутл.* — кечкенәм, нәнием; *„Поди сюда, клоп“, — сказал он* — „Кил бире, кечкенәм“,— диде ул.

**КЛОПИ'НЫЙ** *разг.* — к. клоповый.

**КЛОПО'ВНИК** *м.* — 1. кандала оясы (күп кандалалы бүлмә яки мебель); 2. *бот.* кандала үләне.

**КЛОПО'ВЫЙ** — кандала...-ы; *клоповые гнёзда* — кандала оялары.

**КЛОПОМО'Р** *м.* — кандала үтергеч.

**КЛО'УН** *м.* — клоун, шамакай (циркта мәзәкле номерларны башкаручы артист).

**КЛОУНА'ДА** *ж.* — 1. клоунада (циркта клоуннар катнашы белән эшләнә торган номер); 2. *перен.* шамакайлык, клоунлык.

**КЛО'УНСКИЙ** — клоун ...-ы, клоуннарча...; *клоунские выходки* — клоуннарча кыланышлар.

**КЛОХТА'ТЬ** *несов. разг.* — 1. кытаклау, кытнау, кыткылдау; 2. *перен.* зарлану, сукрану, ахылдау; *ну, довольно тебе клохтать* — җитәр инде сиңа сукранырга.

**КЛО'ЧИТЬ** *несов. обл.* — тузгыту, тузгакландыру (чәчне).

**КЛОЧКОВА'ТЫЙ** — 1. кисәк-кисәк; *клочковатые облака* — кисәк-кисәк болытлар; 2. укмашкан; *клочковатая шерсть* — укмашкан йон.

**КЛОЧО'К** *м.* — кечкенә тотам, кечкенә кисәк, бер уч, бер кисәк; *клочок бумаги* — кәгазь кисәге; *клочок сена* — бер уч печән; *клочок земли* — җир кисәге (бер карыш җир).

**КЛУБ** I *м.* — клуб.

**КЛУБ** II *м.* — 1. *устар.* йомгак; *клуб ниток* — җеп йомгагы; 2. өермә; *клубы пыли* — тузан өермәләре. ◇ **Дым из трубы валил клубом** — төтен морҗадан бөтерелеп (ургылып) чыга иде.

**КЛУБЕНЁК** *м. бот.* — төерчек (кайбер

үсемлекләрнең тамырларында була торган азотлы төер).

**КЛУ'БЕНЬ** *м. бот.*— бүлбе (бәрәңге бүлбесе).

**КЛУБЕНЬКО'ВЫЙ** *бот.*— 1. орылы, төерле; *клубеньковые растения* — орылы үсемлекләр; 2. оры...-ы; *клубеньковые бактерии* — оры бактерияләре.

**КЛУБИ'ТЬ** *несов.*— өереп күтәрү, бөтереп күтәрү; *ветер клубит пыль* — җил тузанны өереп күтәрә.

**КЛУБИ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. бөтерелеп күтәрелү; ургылып күтәрелү; *пыль клубится по дороге* — юлда тузан бөтерелеп күтәрелә; *дым клубился над фабричной трубой* — фабрика трубасыннан төтен ургылып күтәрелә иде; 2. *поэт.* ургылып агу; бөтерелә-бөтерелә агу.

**КЛУБНЕПЛО'Д** *м. бот. с.-х.*— бүлбетамыр (бәрәңге, җир грушасы һ. б.).

**КЛУБНИ'КА** *ж. мн.* нет — җир җиләге (җимеше һәм үсемлеге).

**КЛУБНИ'ЧКА** *ж. мн.* нет, *разг.* — 1. к. клубника; 2. *перен. фам. эвф. (что-н. нескромное, эротическое)* әдәпсез кыланыш, гыйш-гашрәт.

**КЛУБНИ'ЧНИК** *м.*— 1. *обл.* җир җиләклек; 2. *перен. простореч. неодобр.*— гыйшгашрәтче, гыйш-гашрәт сөюче; *ненавижу клубничку и клубничников* (Достоевский)— гыйш-гашрәтне һәм гыйш-гашрәтчеләрне җенем сөйми.

**КЛУБНИ'ЧНЫЙ** — 1. җир җиләге ...-ы; *клубничное варенье* — җир җиләге вареньесы; 2. *перен. разг. неодобр.* әдәпсез, гыйш-гашрәт турындагы; *клубничные разговоры*— әдәпсез сөйләшүләр, гыйш-гашрәт турындагы сөйләшүләр.

**КЛУ'БНЫЙ** — клуб...-ы; *клубная работа* — клуб эше.

**КЛУБО'К** *м.*— 1. йомгак; *клубок ниток* — җеп йомгагы; 2. *перен.* күплек; *клубок противоречий* — каршылыкларның күплеге (каршылыклар йомгагы). ◇ **Слёзы клубком подкатили к горлу** — күз яшьләрем тамагыма төер булып утырды.

**КЛУ'МБА** *ж.*— клумба, чәчәк түтәле, чәчәклек.

**КЛУП(П)** *м. тех.* — клуп (трубаларга винт сырлары ясау коралы).

**КЛУ'ША** *ж. обл.*— утырган тавык, кыртлый торган тавык; 2. *перен. простореч. бран.* аңгыра хатын, булдыксыз хатын.

**КЛЫК** *м.*— казык теш.

**КЛЫКА'СТЫЙ** — зур казык тешле.

**КЛЮВ** *м.*— томшык, кош борыны.

**КЛЮЗ** *м. мор.* — клюз (корабль борынында якорь чылбыры үткәрү өчен тишек).

**КЛЮКА'** *ж.*— кәкре башлы таяк; *старик с клюкой* — кәкре башлы таяк тоткан (таякка таянган) карт.

**КЛЮ'КАТЬ** *несов. простореч. фам.* — 1. аз гына төшерү (эчү); 2. эчүгә күнел бирү; 3. *обл.* чуку; сугу.

**КЛЮ'КАТЬСЯ** *несов. простореч.* — йөзтүбән егылу, борын белән төшү.

**КЛЮ'КВА** *ж. мн.* нет — мүк җиләге. ◇ **Вот так клюква** — менә сиңа кирәк булса.

**КЛЮ'КВЕННЫЙ** — мүк җиләге ...-ы; *клюквенный кисель* — мүк җиләге кисәле.

**КЛЮ'КНУТЬ** *сов. простореч. фам.* — 1. төшереп (эчеп) алу; 2. *обл.* чукып алу; сугып алу.

**КЛЮ'КНУТЬСЯ** *сов. простореч.*— к. клюкаться.

**КЛЮ'НУТЬ** *однокр.*— 1. *(о птице)* чуку, чукып алу; 2. *(о рыбе)* чиртү, чиртеп кую.

**КЛЮЧ** I *м.* — 1. ачкыч; 2. *перен.* сер; *я нашел ключ к пониманию этого странного случая* — мин бу сәер вакыйганы аңлауның серен таптым; 3. *перен.* аңлатма; *ключ к трагедиям Шекспира* — Шекспир трагедияләренә аңлатма. ◇ **Отпереть золотым ключом** *разг.*— взятка биреп берәр теләккә ирешү.

**КЛЮЧ** II *м.* — *(источник)* чишмә, кизләү.

**КЛЮЧ** III *м. архит.* — гөмбәзнең иң өске ташы.

**КЛЮЧА'РЬ** *м. устар.*— ачкыччы.

**КЛЮЧЕВИ'НА** *ж. обл.*— сазлык, чишмә сазлыгы.

**КЛЮЧЕВО'Й** I — ачкыч ...-ы; *ключевая бородка* — ачкыч балтасы.

**КЛЮЧЕВО'Й** II — чишмә...-ы; *ключевая вода* — чишмә суы.

**КЛЮ'ЧИК** *м.*— кечкенә ачкыч.

**КЛЮЧИ'ЦА** *ж. анат.* — умрау, умрау сөяк, ядәч сөяге.

**КЛЮ'ЧНИК** *м.*, **КЛЮ'ЧНИЦА** *ж. истор.*— ачкыччы (өйдә, семьяда азыклар запасын саклау, аларны тоту эшләрен башкаручы).

**КЛЮ'ШКА** *ж.* — кәшәкә (шар сугу уенында, мәсәлән, хоккей уенында кулланыла торган кәкре башлы таяк).

**КЛЯ'КСА** *ж. разг.*— тап, кара табы (кәгазьгә тамган кара табы).

**КЛЯ'НЧИТЬ** *несов. разг.* — теләнеп сорау, ялынып сорау; сорап йөдәтү.

**КЛЯП** *м. обл.*— keләп (тешләмәсен өчен хайван авызына тыгыла торган агач кисәге, кычкырмасын өчен кеше авызына тыгыла торган чүпрәк төргәге).

**КЛЯСТЬ** *несов. книж. ритор.*— каргау, каһәрләү, ләгънәт уку.

**КЛЯ'СТЬСЯ** *несов.*— ант итү, антлы вәгъдә бирү.

**КЛЯ'ТВА** *ж.*— ант; тантаналы вәгъдә. ◇ **Аннибалова** или **Аннибаловская клятва** — мәңгелек ант, һичбер бозмаслык ант.

**КЛЯ'ТВЕННЫЙ** *книж.* — антлы, ант белән ныгытылган.

**КЛЯТВОПРЕСТУПЛЕ'НИЕ** *ср. книж.*— антны бозу.

**КЛЯТВОПРЕСТУ'ПНИК** *м.*, **КЛЯТВОПРЕСТУ'ПНИЦА** *ж. книж.* — антын бозучы.

**КЛЯ'УЗА** *ж. простореч.* — 1. әләк, гайбәт, яла, донос; 2. *устар.* вак-төяк эшләр өчен судлашу.

**КЛЯ'УЗНИК** *м.*, **КЛЯ'УЗНИЦА** *ж.*— әләкче, гайбәтче, яла ягучы; юк-бар өчен судлашучы.

**КЛЯ'УЗНИЧАТЬ** *несов. простореч.* —

әләкләү, гайбәт сату, гайбәт тарату; судлашу, дәгъвалашу.

**КЛЯ'УЗНИЧЕСТВО** *ср. мн.* нет — гайбәтчелек, әләкчелек.

**КЛЯ'УЗНЫЙ** *простореч.* — 1. дәгъвалы, күңелсез; *кляузное дело* — күңелсез эш, дәгъвалы эш; 2. бәйләнчек, гайбәтчел, вакчыл; *кляузный человек* — бәйләнчек кеше, гайбәтчел кеше.

**КЛЯ'ЧА** *ж.* — 1. арык ат, зәгыйфь ат, „корчангы тай"; 2. *перен. разг. фам.* йончыган кеше, зәгыйфь кеше.

**КНАРУ'ЖИ** *нареч. простореч.* — тышка таба.

**КНЕЛЬ** *ж. кулин.* — ит умачы, балык умачы (чабылган иттән яки балыктан ясалган умач).

**КНЕХТ** *м. мор.* — кнехт (судно палубасында яки пристаньда арканнарны, бауларны бәйләү өчен тәбәнәк юан багана).

**КНИ'ГА** *ж.* — 1. китап; 2. кенәгә, дәфтәр; *кассовая книга* — касса кенәгәсе, касса дәфтәре.

**КНИГОВЕ'Д** *м.* — книговед (китап белеме белгече).

**КНИГОВЕ'ДЕНИЕ** *ср. мн.* нет — китап белеме (культураның аерым бер күренеше һәм производство продукты буларак китап турындагы барлык белемнәрне эченә алган фән).

**КНИГОЕ'Д** *м.* — 1. *зоол.* китап корты (китапларга, иске кәгазьләргә оялый торган корт); 2. *пренебр.* хәрефкә ябышып ятучы.

**КНИГОИЗДА'ТЕЛЬ** *м.* — китап бастыручы.

**КНИГОИЗДА'ТЕЛЬСКИЙ** — китап бастыру...-ы; китап бастыручылык...-ы; *книгоиздательское дело* — китап бастыручылык эше.

**КНИГОИЗДА'ТЕЛЬСТВО** *ср.* — китап бастыручылык, китап бастыручы предприятие, издательство, нәшрият.

**КНИГОЛЮ'Б** *м.* — китап һәвәскәре, китап сөюче.

**КНИГОНО'ША** *м.* и *ж.* — 1. китап таратучы (укучыга китаплар илтеп бирүче); 2. китаплар сатып йөрүче.

**КНИГОПЕЧА'ТАНИЕ** *ср. мн.* нет — китап басу.

**КНИГОПЕЧА'ТНИК** *м. устар. книж.* — китап басучы.

**КНИГОПЕЧА'ТНЫЙ** — китап басу ...-ы; *книгопечатная машина* — китап басу машинасы.

**КНИГОПРОДА'ВЕЦ** *м.* — китап сатучы.

**КНИГОТОРГО'ВЛЯ** *ж. мн.* нет — китап сәүдәсе.

**КНИГОТОРГО'ВЫЙ** — китап сәүдәсе...-ы; *книготорговый сектор* — китап сәүдәсе секторы.

**КНИГОХРАНИ'ЛИЩЕ** *м.* — 1. китап саклау урыны; 2. зур китапханә.

**КНИ'ЖИЩА** *ж. простореч.* — зур китап.

**КНИ'ЖКА** I *ж.* — 1. кечкенә китап; 2. кенәгә; *сберегательная книжка* — саклык кенәгәсе.

**КНИ'ЖКА** II *ж. анат.* — кырык карта.

**КНИ'ЖНИК** *м.* — 1. китап сөюче, китап һәвәскәре; 2. *старин.* начётчик (дини китапларны күп укыган кеше); 3. *спец.* китап сәүдәсендә эшләүче.

**КНИ'ЖНО** *нареч.* — китапча, китапчалатып.

**КНИ'ЖНОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. китапчалык; 2. китаплар белән артык мавыгу.

**КНИ'ЖНЫЙ** — 1. китап...-ы; *книжная полка* — китап шүрлеге; 2. *перен.* китапчыл, практикадан ерак; *книжный человек* — китапчыл кеше, практикадан ерак кеше; 3. китапча, китап...-ы; *книжный стиль* — китапча стиль, китап стиле.

**КНИЖО'НКА** *разг. уничижит.* — начар китап, алама китап, китап кисәге.

**КНИ'ЗУ** *нареч.* — аска, аска таба, түбәнгә, түбәнгә таба.

**КНО'ПКА** *ж.* — кнопка, каптырма.

**КНО'ПОЧНЫЙ** — кнопка...-ы; кнопкалар...-ы; *кнопочное производство* — кнопка производствосы; *кнопочная коробка* — кнопкалар тартмасы.

**КНУТ** *м.* — 1. чыбыркы; 2. *перен.* җәбер, золым, кысу, кочләү.

**КНУТОБО'Й** *м. устар.* — камчы белән җәзалаучы (палач).

**КНУТОБО'ЙНИЧАТЬ** *несов. устар.* — 1. камчы белән җәзалау; 2. *перен. неодобр.* җәберләү, көчләү, җәзалау.

**КНУТОВИ'ЩЕ** *ср.* — чыбыркы сабы.

**КНУТРИ'** *нареч. устар. простореч.* — эчкә таба.

**КНЯГИ'НЯ** *ж. истор.* — князь хатыны.

**КНЯЖЕ'НИЕ** *ср. истор.* — 1. князьлек итү; 2. князьлек.

**КНЯ'ЖЕСКИЙ** *истор.* — 1. князь...-ы; *княжеский дом* — князь өе; 2. князьлек...-ы; князьләр...-ы; *княжеский род* — князьләр нәселе.

**КНЯ'ЖЕСТВО** *ср.* — 1. *истор.* князьлек; 2. *дореволь.* князьлек дәрәҗәсе.

**КНЯ'ЖИЙ** *устар.* — к. княжеский.

**КНЯ'ЖИТЬ** *несов. истор.* — князьлек итү.

**КНЯ'ЖИЧ** *м. истор.* — князь малае.

**КНЯЖНА'** *ж. истор.* — князь кызы.

**КНЯЗЬ** *м.* (*мн.* князья) *истор.* — князь.

**КО** *предлог* — *к.* к.

**КОАЛИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. полит.* — коалициягә керү, союзга керү.

**КОАЛИЦИО'ННЫЙ** *полит.* — коалицион; *коалиционная политика* — коалицион политика.

**КОАЛИ'ЦИЯ** *ж. полит.* — коалиция (1. гомуми максатларга ирешү өчен иректе рәвештә берләшү; 2. ике яки берничә дәүләтнең башка бер дәүләткә каршы төзелгән политик союзы; 3. берләшеп хөкүмәт оештыру һәм анда катнашу өчен политик партияләр тарафыннан төзелгән союз).

**КО'БАЛЬТ** *м. мн.* нет — кобальт (1. *хим.* тимердән катырак, көмешсыман ак металл; 2. куе зәңгәр төстәге буяу).

**КО'БАЛЬТОВЫЙ** — 1. кобальт...-ы; *кобальтовый цвет* — кобальт төсе; 2. кобальт (тан ясалган); *кобальтовое стекло* — кобальттан ясалган пыяла.

**КОБЁЛ** *м. обл.* — агач төбе, субай, казык.
**КОБЕ'ЛЬ** *м.* — ата эт.
**КОБЕ'НИТЬСЯ** *несов. простореч.* — назланып кыстату; тискәреләнү, киреләнү.
**КО'БЗА'** *ж.* — кобза (Украина думбрасы).
**КОБЗА'РЬ** *м.* — кобзарь (кобзада үзе уйнап җырлаучы Украина халык җырчысы).
**КО'БРА** *ж. зоол.* — күзлекле елан.
**КОБУРА'** *ж.* — кобура (1. револьвер кынысы, кабы; 2. *воен.* иыргә тагыла торган кечкенә күн сумка).
**КО'БЧИК** *м. зоол.* — лачын(ның бер төре).
**КОБЫ'ЛА** I *ж.* — 1. бия, байтал; 2. *перен* тупас хатын, зур гәүдәле хатын.
**КОБЫ'ЛА** II *ж.* — кобыла (1. *спорт.* гимнастика күнегүләре башкару өчен күн белән тышланган дүрт аяклы стан; 2. *истор.* тән җәзасы бирeләчәк кешене бәйләп кую өчен скамья).
**КОБЫ'ЛИЙ** — бия...-ы; *кобылье молоко* — бия сөте.
**КОБЫ'ЛИЦА** *ж. книж.* — бия, байтал.
**КОБЫ'ЛКА** I *ж.* — бия, бия тай.
**КОБЫ'ЛКА** II *ж.* — скрипка глашасы.
**КОБЫ'ЛКА** III *ж. зоол.* — вак чикерткә.
**КОБЫЛЯ'ТИНА** *ж. мн. нет, обл.* — бия ите, ат ите.
**КОВА'ЛЬ** *м. обл.* — тимерче.
**КО'ВАНЫЙ** — 1. чүкеп ясалган, таптап ясалган; *кованый меч* — чүкеп ясалган кылыч; 2. тимерләнгән; *кованый сундук* — тимерләнгән сандык; 3. *перен.* тасвирлы, ачык аңлаешлы, чарланган; *кованый стиль* — ачык аңлаешлы стиль.
**КОВА'РНОСТЬ** *ж. мн. нет* — эчкерлелек, мәкерлелек.
**КОВА'РНЫЙ** — эчкерле, мәкерле, хәйләкәр, явыз ниятле.
**КОВА'РСТВО** *ср.* — эчкерлелек, мәкер, явыз ният, астыртын хәйлә.
**КОВА'ТЬ** *несов.* — 1. чүкү, чүкеп ясау, таптау, таптап ясау; сугу; *ковать железо* — тимер чүкү, тимер таптау; *куй железо, пока горячо* — тимерне кызуында сук; 2. дагалау; *ковать коня* — ат дагалау; 3. *устар. (заковывать)* богаулау; 4. *перен. книж.* көч куеп ирешү, өзлексез тырышып ирешү; *ковать своё счастье* — көч куеп үз бәхетенә ирешү.
**КОВА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. чүкелү, чүкеп ясалу, тапталу, таптап ясалу, сугылу; 2. дагалану; 3. *устар.* богаулану.
**КОВА'Ч** *м. обл.* — тимерче.
**КОВБО'Й** *м.* — ковбой (Төньяк Америкада атлы көтүче).
**КОВБО'ЙКА** *ж.* — ковбойка (1. киң читле эшләпә; 2. шакмаклы күлмәк төре).
**КОВЁР** *м.* — келәм, палас, ковёр.
**КОВЕ'РКАТЬ** *несов.* — 1. вату, бозу, җимерү; *коверкать машину* — машинаны вату; *дурное воспитание коверкает детей* — начар тәрбия баланы боза; 2. бозып әйтү; бозып сөйләү; *коверкать французские слова* — француз сүзләрен бозып әйтү; *коверкать чужую мысль* — башка берәүнең фикерен бозып сөйләү.
**КОВЕ'РКАТЬСЯ** *несов. страд.* — ватылу, бозылу, җимерелү.
**КОВЕРКО'Т** *м.* — коверкот (кыйммәтле йон материя).
**КОВЕРКО'ТОВЫЙ** — коверкот..., коверкот(тан тегелгән); *коверкотовое пальто* — коверкот пальто.
**КО'ВКА** *ж. мн. нет* — 1. чүкү, таптау (тимерне); 2. дагалау (атны).
**КО'ВКИЙ** — чүкүгә бирелүчән, чүкелүчән.
**КО'ВКОСТЬ** *ж. мн. нет, тех.* — чүкелүчәнлек.
**КО'ВОЧНЫЙ** *тех.* — чүкү...-ы; *ковочный процесс* — чүкү процессы.
**КОВРИ'ГА** *ж. обл.* — бөтен икмәк, бер бөтен ипи.
**КОВРИ'ЖКА** *ж.* — 1. *разг.* пряник; 2. *обл.* кечкенә бөтен икмәк. ◇ **Ни за какие коврижки** *разг. фам.* — һичбер, һич тә, бер дә.
**КО'ВРИК** *м.* — кечкенә палас, кечкенә келәм.
**КОВРО'ВЫЙ** — 1. келәм...-ы; *ковровое производство* — келәм производствосы; 2. келәмсыман, келәмгә охшаган (күренеше яки сыйфаты ягыннан).
**КОВРО'ВЩИК** *м.*, **КОВРО'ВЩИЦА** *ж.* — келәмче.
**КОВШ** *м.* — 1. чүмеч, соскы; 2. мөшкә кашыгы (тегермәндә).
**КО'ВШИК** *м.* — кечкенә чүмеч.
**КО'ВЫ** *мн. книж. устар.* — явыз ниятләр, мәкерле эшләр.
**КОВЫ'ЛЬ** *м. мн. нет, бот.* — кылган (үлән).
**КОВЫ'ЛЬНИК** *м. охот.* — дала куяны.
**КОВЫЛЬНУ'ТЬ** *однокр.* — к. ковылять.
**КОВЫ'ЛЬНЫЙ** — кылган...-ы; *ковыльные степи* — кылган далалары.
**КОВЫЛЯ'ТЬ** *несов. разг.* — тыйтаклап бару, чатанлап бару, аксаклап бару; аякларны көчкә генә сөйрәп, акрын бару.
**КОВЫРНУ'ТЬ** *однокр. разг.* — казып куптарып алу.
**КОВЫРНУ'ТЬСЯ** *сов. простореч.* — гөрселдәп егылу, шап итеп сгылу.
**КОВЫРЯ'ТЬ** *несов. разг.* — 1. казу, казып куптару, актару; *ковырять землю* — җир актару; *ковырять в зубах* — тешләрне казу; 2. *перен. (неумело делать)* эштер-өштер китерү, ничек житте шулай эшләү. ◇ **Ковырять лапти** *обл.* — чабата үрү.
**КОВЫРЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. *(в чём)* казыну, чокыну; 2. *перен. разг. пренебр. (медленно делать)* казыну, казынып тору.
**КОГДА'** — 1. *вопросит. нареч.* кайчан, кайвакытта; *когда он придёт?* — ул кайчан килер?; 2. *неопред. нареч.* кайчан да булса; берәр чакта; *слыхал ли ты когда, чтоб мёртвые из гроба выходили?* (Пушкин) — мәетләрнең кабердән чыкканнарын синең кайчан да булса ишеткәнең бармы? 3. *неопред. нареч.* кайчакта; *когда можно, когда нельзя* — кайчакта ярый, кайчакта

ярамый; 4. *условный союз* әгәр...-са, әгәр дә... икән; *когда в товарищах согласья нет, на лад их дело не пойдёт* (Крылов) — әгәр дуслар булмасалар бер киңәштә, жай тапмаслар алар эштә; 5. *временной союз* ...-ганда, ...-гач; *когда шли* — барганда; *когда пришли* — килгәч. ◇ Есть когда! *разг. фам.* — вакыт юк, вакыт бар иде ди („вакыт юк" мәгънәсендә).

**КОГДА'-ЛИБО, КОГДА'-НИБУДЬ** *нареч.* — кайчан да булса, кайчан булса да, берәр вакытны.

**КОГДА'-ТО** *нареч.* — 1. кайчандыр; *когда-то мы были знакомы* — кайчандыр без таныш идек; 2. кайчан, кайчан әле; *когда-то он соберётся!* — кайчан җыеныр әле ул!

**КОГО'** — кемнән, кемне; *кого ты стесняешься?* — син кемнән тартынасың? *кого ты видел?* — син кемне күрдең?

**КОГО'РТА** *ж.* — когорта (1. *истор.* борынгы Римдә 600 кешелек гаскәри берләшмә; 2. *перен. ритор. торж.* бердәм туплаңган кешеләр группасы).

**КОГОТО'К** *м. разг.* — кечкенә тырнак (кошларда һәм җәнлекләрдә).

**КО'ГОТЬ** *м.* — 1. тырнак (кошларда һәм җәнлекләрдә); 2. *перен.* тырнак; *попасть в когти врага* — дошман тырнагына эләгү.

**КОГТИ'СТЫЙ** *книж.* — үткен тырнаклы.

**КОГТИ'ТЬ** *несов. обл.* — тырнаклар белән ерткалау, тырнаклар белән өзгәләү.

**КОД** *м. спец.* — код (шартлы кыскартмалар исемлеге, мәсәлән, телеграф эшендә, сигнал бирүдә).

**КО'ДА** *ж.* — кода (1. *муз.* музыкаль пьесаның йомгаклау өлеше; 2. *лит.* юл саны төгәл булырга тиешле шигъри әсәрләрнең, мәсәлән, 14 юллы сонетның, ахырына шул төгәл юллардан тыш өстәлгән юл).

**КОДЕИ'Н** *м. мн.* нет, *апт.* — кодеин (ютәлне бетерә торган дару).

**КО'ДЕКС** *м.* — кодекс (1. системалаштырылган законнар җыелмасы; 2. *перен. книж.* гореф-гадәт, гадәт-йола кагыйдәләре).

**КОДИФИКА'ТОР** *м. книж.* — кодификатор, кодификация белән шөгыльләнүче, кодификацияләүче.

**КОДИФИКАЦИО'ННЫЙ** — кодификация...-ы; *кодификационный отдел* — кодификация бүлеге.

**КОДИФИКА'ЦИЯ** *ж.* — кодификация (билгеле бер вакыт эчендә чыгарылып, хәзерге көндә гамәлдә булган законнарны системалы бер бөтенгә (кодекска) туплау, теркәү).

**КОДИФИЦИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.* — кодификацияләү, кодекска туплау.

**КО'Е-ГДЕ'** *нареч.* — кайбер урыннарда, кайбер җирләрдә; анда-монда, анда-санда, ара-тирә, урыны-урыны белән.

**КО'Е-КА'К** *нареч.* — 1. *(еле-еле)* көчкә-көчкә генә, чак-чак, көч-хәл белән; 2. *(небрежно)* ничек житте шулай, алай-болай гына, эштер-өштер генә, эштер-өштер итеп.

**КО'Е-КАКО'Й** *неопред. местоим.* — 1. кайбер; *позвольте обратиться к вам с кое-какими* (или *кое с какими*) *просьбами* — сезгә кайбер үтенечләр белән мөрәҗәгать итәргә рөхсәт итегез; 2. аз-маз, вак-төяк, беркадәр; *завелись кое-какие денжонки* — кулга аз-маз акча да керде.

**КО'Е-КТО'** *неопред. местоим.* — кемнәрдер, кайберәүләр, кайбер кешеләр.

**КО'ЕЧНЫЙ** — койка...-ы; *коечный чехол* — койка чехолы; 2. койкада ятучы..., больницада ятучы...; *коечный больной* — койкада (больницада) ятучы авыру.

**КО'Е-ЧТО'** *неопред. местоим.* — нәрсәдер, нидер; кайбер әйберләр.

**КО'ЖА** *ж.* — 1. *(на живом теле)* тире; 2. *(выделанная)* күн; 3. кабык; *яблоко с толстой кожей* — калын кабыклы алма. ◇ Из кожи (вон) лезть *разг.* — җан-фәрманга тырышу, тиргә батып тырышу.

**КОЖА'Н** I *м.* — кожан (күн кием).

**КОЖА'Н** II *м. зоол.* — зур ярканат.

**КО'ЖАНКА** *ж.* — 1. *обл.* күннән тегелгән әйбер; 2. кожанка (күн куртка).

**КО'ЖАНЫЙ** — күн(нән тегелгән); *кожаная обувь* — күн аяк киеме.

**КОЖЕ'ВЕННИК** *м.* — к. кожевник.

**КОЖЕ'ВЕННЫЙ** — 1. күн...-ы; *кожевенный завод* — күн заводы; 2. күн...; *кожевенный товар* — күн товар.

**КОЖЕ'ВНИК** *м.* — 1. күнче, күн производствосы эшчесе; 2. *устар.* күн сатучы.

**КОЖЕДЁР** *м. спец.* — тире тунаучы.

**КОЖЕЕ'Д** *м. зоол.* — тиреашар, тире корткычы.

**КОЖЕМЯ'КА** *м. устар.* — тире иләүче.

**КОЖИМИ'Т** *м. мн.* нет, *спец.* — кожимит, ясалма күн.

**КО'ЖИСТОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. калын тиреләлек, тыгыз тиреләлек; 2. калын кабыклылык, тыгыз кабыклылык.

**КО'ЖИСТЫЙ** — 1. калын тиреле, тыгыз тиреле; 2. калын кабыклы, тыгыз кабыклы; 3. тиресыман; *кожистая оболочка* — тиресыман тышча.

**КО'ЖИЦА** *ж.* — 1. *(тонкая кожа)* юка тире; 2. яры, кабык; *кожица молодого листа* — яшь яфракның ярысы (кабыгы).

**КО'ЖНИК** *м. разг.* — тире авырулары врачы.

**КО'ЖНЫЙ** *спец.* — тире...-ы; *кожные болезни* — тире авырулары.

**КОЖУРА'** *ж. мн.* нет — кабык; *кожура апельсина* — апельсин кабыгы.

**КО'ЖУХ** *м.* — 1. *обл.* күн кием, бәрән толып; 2. *(покрышка)* кожух, капкач, каплавыч, футляр; 3. *обл.* кожан.

**КОЗА'** *ж.* — 1. *зоол.* кәҗә; 2. *тех.* күтәргеч (авыр әйберләр күтәрү машинасы).

**КОЗЁЛ** I *м. зоол.* — кәҗә тәкәсе. ◇ Козёл отпущения — гөнаһларны йолу тәкәсе (бүтәннәрнең гаебе, җаваплылыгы һәрвакыт аның өстенә ыргытыла торган кеше турында әйтелә). Пустить козла в огород — кәҗәне кәбестә сакларга кую.

**КОЗЁЛ** II *м. спорт.* — кузла (гимнастика күнегүләре башкару өчен кулланыла торган дүрт аяклы стан).

**КОЗЕЛКИ'** *ед.* нет, *спец.* — кечкенә кузла (мәсәлән, утын кисү өчен).

**КОЗЕРО'Г** *м.* — кыргый кәҗә(нең бер төре). ◇ **Тропик Козерога** — көньяк тропигы.

**КО'ЗИЙ** — кәҗә...-ы; *козье молоко* — кәҗә сөте. ◇ **Козья ножка** *мед.* — теш суыру коралы.

**КОЗЛЁНОК** *м.* (*мн.* козлята) — кәҗә бәтие, кәҗә бәрәне.

**КОЗЛЕТО'Н, КОЗЛИТО'Н** *м. разг. шутл.* — ягымсыз тавыш, ямьсез тавыш, кәҗә тавышы (җырлаучының).

**КО'ЗЛИК** *м.* — яшь кәҗә тәкәсе.

**КОЗЛИ'НЫЙ** — кәҗә тәкәсе...-ы; *козлиная борода* — кәҗә тәкәсе сакалы.

**КОЗЛИ'ЩЕ** *м.* — зур кәҗә тәкәсе.

**КОЗЛО'ВЫЙ** — кажул..., кәҗә күненнән эшләнгән; *козловые ичиги* — кажул читек.

**КО'ЗЛЫ** *ед.* нет — 1 *(передок экипажа)* кузла, ат башы; 2. кузла (утын кискәндә кулланыла торган дүрт аяклы стан).

**КОЗЛЯ'ТИНА** *ж. мн.* нет — кәҗә ите.

**КО'ЗНИ** *мн.* (*ед.* кознь редко) *книж. устар.*—явыз уйлар, явыз ниятләр, хәйләләр (берәр кешегә аның дошманнары тарафыннан эшләнә торган явызлыклар).

**КОЗОВО'Д** *м. спец.* — кәҗәләр үрчетүче, кәҗәләр асраучы.

**КОЗОВО'ДСТВО** *ср. мн.* нет, *спец.* — кәҗә үрчетүчелек, кәҗә асраучылык.

**КОЗОВО'ДЧЕСКИЙ** — кәҗәләр үрчетү...-ы, кәҗәләр асрау...-ы; *козоводческий совхоз* — кәҗәләр үрчетү совхозы.

**КОЗОДО'Й** *м. зоол.* — төн күгәрчене.

**КОЗУ'ЛЯ** *м. зоол.* — кыр кәҗәсе.

**КОЗЫРЁК** *м.* — козырёк (баш киемендә).

**КОЗЫРНО'Й** — к. козырный.

**КОЗЫРНУ'ТЬ** *однокр.* — 1. к. козырять 1, 3; 2. мактану, мактанып алу, мактанып кую, шапырынып алу, шапырынып кую.

**КОЗЫ'РНЫЙ** — козырь...-ы; *козырный туз* — козырь тузы.

**КО'ЗЫРЬ** *м.* — 1. козырь; *ходить с козыря* — козырь белән йөрү; 2. *перен.* чарә, өстенлек; *последний козырь* — соңгы чара. ◇ **Ходить козырем** *простореч.* — кукраеп йөрү.

**КОЗЫРЯ'ТЬ** *несов.* — 1. козырь белән йөрү, козырь белән чыгу; козырять итү; *козырять тузом* — козырь тузы белән йөрү; 2. *перен. просторец.* мактану, шапырыну; *козырять своими знаниями* — үзеңнең белемнәрең белән шапырыну; 3. *воен.* честь бирү.

**КОЗЯ'ВКА** *ж. зоол.* — 1. вак бөҗәк, вак корт; 2. *фам. пренебр.* әһәмиятсез кеше.

**КОЙ** *местоим. вопросит. обл.* — ничә, ничәнче, нинди; *а кой тебе годик?* — ә синә ничәнче яшь?

**КОЙ-ГДЕ'** *нареч.* — к. кое-где.

**КО'ЙКА** *ж.* — койка, кровать.

**КОЙ-КА'К, КОЙ-КАКО'Й, КОЙ-КОГДА', КОЙ-КТО', КОЙ-ЧТО'**—к. кое-как и т. д.

**КОК I** *звукоподраж. просторец.* — шап; *кок одно яйцо о другое* — бер йомырканы икенчесенә шап (итеп бәрде).

**КОК II** *м. разг. устар.* — чәч бөтеркәсе.

**КОК III** *м. мор.* — кок, корабль повары.

**КО'КА** *ж. детск.* — йомырка, күкәй (балалар телендә).

**КОКАИ'Н** *м. фармац.* — кокаин (операция ясаганда авырту сизүне бетерү өчен тәнгә җибәрелә торган яки кәефне күтәрү өчен наркоманнар исни торган агулы алколоид).

**КОКАИНИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *мед.* — кокаинизм (1. кокаинны күп кулланудан була торган психик авыру; 2. *разг.* кокаин куллануга бирелү).

**КОКАИНИ'СТ** *м.*, **КОКАИНИ'СТКА** *ж.*— кокаин иснәүче.

**КОКАИ'НОВЫЙ** — кокаин...-ы; *кокаиновый препарат* — кокаин препараты.

**КОКА'РДА** *ж.* — кокарда (баш киеменең маңгай өлешенә кадап куела торган значок).

**КО'КАТЬ** *несов. просторец. фам.* — 1. бәреп вату; 2. сугу, кундыру.

**КО'КАТЬСЯ** *несов. просторец. фам.* — 1 бәрелеп ватылу; 2. бәрелү, орылу.

**КОКЕ'ТКА** *ж.* — 1. кокетка, көяз, кыланчык, чытлык; 2. *(верхняя часть платья)* кокетка; *платье с кокеткой* — кокеткалы күлмәк.

**КОКЕ'ТЛИВО** *нареч.* — көязләнеп, кыланчыкланып, чытлыкланып.

**КОКЕ'ТЛИВОСТЬ** *ж. мн.* нет — көязлек, кыланчыклык.

**КОКЕ'ТЛИВЫЙ** — 1. көяз, кыланчык; 2. *разг. фам.* матур җыйналган, җиһазланган (мәсәлән, өй).

**КОКЕ'ТНИЧАТЬ** *несов. разг.* — көязләнү, кыланчыклану, чытлыклану.

**КОКЕ'ТСТВО** *ср. мн.* нет — көязлек, кыланчыклык.

**КО'ККИ** *мн.* (*ед.* кокк редко) *мед.* — шарсыман микроблар.

**КОКЛЮ'Ш** *м. мн.* нет, *мед.* — бума ютәл, коклюш.

**КОКЛЮ'ША** *ж. спец.* — җияк, тамбур инәсе (челтәр бәйләү өчен).

**КОКЛЮ'ШНЫЙ** — бума ютәл...-ы; коклюш...-ы; *коклюшная рвота* — бума ютәл укшытуы.

**КО'КНУТЬ** *сов. просторец.* — к. кокать.

**КО'КНУТЬСЯ** *сов. просторец.* — к. кокаться.

**КО'КОН** *м.* — кузы, кокон (күбәләк кортының курчаклык стадиясенә баруы дәвамында үз эченнән чыгарган җепселләргә төренүеннән барлыкка килгән йомгак, мәсәлән, ефәк коконы).

**КОКО'РА** *ж. спец.* — тамырлы бүрәнә (тамыры белән бергә йолкынып алынган агач).

**КОКО'С** *м.* — кокос (агачы һәм чикләвеге).

**КОКО'СОВЫЙ** — кокос...-ы; *кокосовое масло* — кокос мае.

**КОКО'ТКА** *ж.* — сөяркә, азгын хатынкыз (буржуаз җәмгыятьтә).

**КОКО'ШНИК** *м. устар.* — кокошник

(1. төньякта яшәүче рус крестьян хатын-кызларының баш киеме; 2. шул баш киеменә охшатып ясалган архитектура бизәге).

**КОКС** *м. мн.* нет — кокс (ташкүмернең махсус рәвештә кыздырып хәзерләнгән төре).

**КОКСОВА'ЛЬНЫЙ** — кокслау...-ы; *коксовальная печь* — кокслау мичe.

**КОКСОВА'НИЕ** *ср. мн.* нет, *тех.* — кокслау, кокска әйләндерү; кокслану, кокска әйләнү.

**КОКСО'ВАННЫЙ** — кокслаңган, кокска әйләндерелгән.

**КОКСОВА'ТЬ** *несов. тех.* — кокслау, кокска әйләндерү (ташкүмерне).

**КОКСОВА'ТЬСЯ** *несов. тех.* — 1. кокслану, кокска әйләнү; 2. *страд.* кокска әйләндерелү.

**КО'КСОВЫЙ** — кокс...-ы; *коксовое производство* — кокс производствосы.

**КОЛ** *м.* — 1. (*мн.* колья) казык; 2. (*мн.* колы) берле билгесе (мәктәптә куела торган иң түбән билге). ◇ **Хоть кол на голове теши** — әйттең ни, әйтмәдең ни, барыбер файдасы юк (тискәре, кире кеше турында).

**КОЛА'ЧИВАТЬ** *многокр. просторечь.* — кыйнаштыргалау.

**КО'ЛБА** *ж. спец.* — колба (тар муенлы, йомры пыяла савыт).

**КОЛБАСА'** *ж.* — колбаса, казылык, тутырма. ◇ **Катись колбасой** *вульг.* — табаныңны ялтырат, үкчәңне күтәр.

**КОЛБА'СКА** *ж.* — к. колбаса.

**КОЛБА'СНИК** *м.* — колбасачы, казылыкчы.

**КОЛБА'СНЫЙ** — колбаса...-ы; казылык...-ы; *колбасная торговля* — колбаса сәүдәсе.

**КОЛДО'БИНА** *ж. разг. обл.* — казылма, сикәлтә; сулы чокыр.

**КОЛДОВА'ТЬ** *несов.* — сихерләү, сихерчелек итү, күз буу.

**КОЛДОВСКО'Й** — 1. сихерчелек...-ы; *колдовские заклинания* — сихерчелек ырымнары; 2. *перен. поэт.* сихерле; *колдовская тишина* — сихерле тынлык.

**КОЛДОВСТВО'** *ср. мн.* нет — сихерчелек.

**КОЛДО'ГОВО'Р** *м.* — колдоговор, коллектив договор.

**КОЛДУ'Н** *м.*, **КОЛДУ'НЬЯ** *ж.* — сихерче, күз буучы.

**КОЛДУНЫ'** *ед.* нет, *кулин. обл.* — вак пәрәмәч.

**КОЛЕБА'НИЕ** *ср.* — 1. калтырау, тирбәнү; тирбәнеш; *колебание маятника* — маятникның тирбәнүе; *колебание струны* — кылның калтыравы; 2. *перен.* икеләнү; *после долгих колебаний я решился переменить профессию* — озак икеләнүләрдән соң мин профессиямне алыштырырга карар бирдем; 3. үзгәреш, үзгәреп тору; *колебание цен* — бәяләрнең үзгәреп торуы.

**КОЛЕБА'ТЕЛЬНЫЙ** *физ.* — тирбәнү...-ы; чайкалып тору...-ы; *колебательные движения* — тирбәнү хәрәкәтләре.

**КОЛЕБА'ТЬ** *несов.* — 1. тирбәтү, селкетү, хәрәкәтләндерү, дулкынландыру; *ветер колеблет верхушки деревьев* — җил агач башларын селкетә (тирбәтә); 2. *перен.* какшату; *колебать авторитет* — авторитетын какшату; 3. *перен.* икеләндерү, шикләндерү, шиккә төшерү; *эти доводы меня нисколько не колеблют* — бу дәлилләр мине һичбер икеләндермиләр.

**КОЛЕБА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. тирбәлү, селкенү, дулкынлану; *вода колебалась* — су тирбәлә (дулкынлана) иде; 2. *перен.* икеләнү, икеләнеп тору, шөбһәләнү, шикләнү; *он долго колебался, прежде чем дать своё согласие* — үзенең ризалыгын биргәнгә кадәр ул озак икеләнеп торды; 3. какшау; *его авторитет стал в последнее время колебаться* — аның авторитеты соңгы вакытта какшый башлады; 4. үзгәреп тору; *цены на продукты всё время колеблются* — азык бәяләре һаман үзгәреп торә; 5. *страд.* тирбәтелү, селкетелү.

**КОЛЕБНУ'ТЬ** *однокр.* — тирбәтеп кую, тирбәтеп алу, селкетеп кую, селкетеп алу, селкетеп җибәрү.

**КОЛЕБНУ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. тирбәнеп кую, селкенеп кую, селкенеп китү; *маятник колебнулся* — маятник тирбәнеп куйды; 2. *перен. (поколебаться в убеждениях)* икеләнеп калу, шиккә төшү.

**КОЛЕ'НКА** *ж. разг.* — тез.

**КОЛЕНКО'Р** *м. мн.* нет — коленкор (арзанлы мамык тукыма). ◇ **Совсем другой коленкор** *просторечь. шутл.* — бөтенләй башка нәрсә, бөтенләй башка эш.

**КОЛЕНКО'РОВЫЙ** — 1. коленкор...-ы; *коленкоровое производство* — коленкор производствосы; 2. коленкор..., коленкордан эшләнгән; *коленкоровый переплёт* — коленкор тыш.

**КОЛЕ'ННЫЙ** — тез...-ы; *коленная чашка* — тез капкачы.

**КОЛЕ'НО** *ср.* — 1. (*мн.* колени) тез, тез буыны; *ушибить колено* — тезне имгәтү; 2. (*мн.* коленья) буын, буынтык, кисәк; *коленья бамбука* — бамбук буыннары; *коленья железной трубы* — тимер трубаның буынтыклары (кисәкләре); 3. (*мн.* коленья и колена) борылма; *в колене речки* — елга борылмасында; 4. (*мн.* колена) *(разветвление рода)* буын. ◇ **Море по колено** — диңгез тубыктан. **Поставить на колени** *перен.*— буйсындыру, тезләндерү. **Посадить на колени** — алга утырту, итәккә утырту. **Давать колено** — 1. кинәт икенче якка борылу (куып барган вакытта); 2. борылыш ясау; *река даёт колено* — елга борылыш ясый.

**КОЛЕНОПРЕКЛОНЕ'НИЕ** *ср. книж. церк.* — тез чүгеп тору, тез чүгү, тезләнү.

**КОЛЕ'НЧАТЫЙ** — буынлы, буыннардан торган; терсәкле; *коленчатый ствол* — буынлы көпшә; *коленчатый вал* — терсәкле вал.

**КО'ЛЕР** *м. живоп.* — төс, төсмер.

**КОЛЁСИКО** *ср. разг. спец.* — бик кечкенә көпчәк, бик кечкенә тәгәрмәч.

**КОЛЕСИ'ТЬ** *несов. разг.* — 1. әйләнеч

юллардан йөрү (атта); 2. төрле юнәлешләрдә күп йөрү.

**КОЛЕ'СНИК** *м. спец.* — көпчәкче, тәгәрмәчче (көпчәк ясаучы яки сатучы).

**КОЛЕСНИ'ЦА** *ж.* — 1. *истор.* ике көпчәкле арба; 2. *устар.* зур тантана вакытларында җигелә торган арба.

**КОЛЁСНЫЙ** — 1. көпчәк...ы; тәгәрмәч ...-ы; *колёсный мастер* — көпчәк (тәгәрмәч) остасы; 2. көпчәкле, тәгәрмәчле; *колёсное кресло* — көпчәкле (тәгәрмәчле) кресло.

**КОЛЕСО'** *ср.* (*мн.* колёса) — 1. көпчәк, тәгәрмәч; *колесо телеги* — арба көпчәге, арба тәгәрмәче; 2. *(мельничное)* чарык; 3. *перен.* барыш, үзгәреш, туктаусыз агып үзгәреп тору. ◇ **Вставлять палки в колесо** *разг.* — тәгәрмәчкә таяк тыгу, эшкә аяк чалу (эшкә комачаулык итү). **Грудь колесом** *разг.* — калку күкрәк.

**КОЛЕСОВА'ТЬ** *несов. истор.* — махсус көпчәккә бәйләп җәзалау.

**КОЛЕ'ЧКО** *ср. разг.* — балдак, кечкенә боҗра.

**КОЛЕЯ'** *ж.* — 1. эз, көпчәк (тәгәрмәч) эзе; 2. *ж.-д.* колея; *широкая колея* — киң колея. ◇ **Жизнь вошла в обычную колею** — тормыш гадәттәге эзенә төште. **Выйти из колеи** — чыгырыннан чыгу, эзеннән чыгу.

**КОЛИ** *союз условный* — әгәр, әгәр дә; ...-сың икән; *коли любишь* — яратасың икән.

**КОЛИ'БРИ** *м. нескл. зоол.* — колибри (бик кечкенә кош).

**КО'ЛИКИ** *мн.* — чәнчү, чәнчү алу; *начались колики в животе* — эчне чәнчү ала башлады.

**КОЛИРОВА'ТЬ** *несов. сад.* — ялгау (агачларны бөре белән).

**КОЛИ'Т** *м. мед.* — колит (юан эчәкнең ялкынсынуы).

**КОЛИ'ЧЕСТВЕННО** *нареч.* — сан ягыннан; *организация значительно выросла количественно* — оешма сан ягыннан шактый үсте.

**КОЛИ'ЧЕСТВЕННЫЙ** — күләм...-ы; сан... -ы; күләм ягыннан; *количественный анализ* — күләм ягыннан анализ; *количественные изменения* — сан үзгәрешләре.

**КОЛИ'ЧЕСТВО** *ср.* — 1. сан; *количество переходит в качество* — сан сыйфатка күчә; 2. микъдар, күләм, сан; *из равных количеств угля и селитры и двух таких же количеств серы можно сделать порох* — тигез микъдарда алынган күмер белән селитрадан һәм шундый ук ике микъдарда аларга кушылган күкерттән дары ясарга мөмкин; 3. *лингв.* сузылыш; *по количеству звуки бывают долгие и краткие* — сузылыш ягыннан авазлар озын һәм кыска булалар.

**КО'ЛКА** *ж. мн.* нет — яру; вату; *колка дров*—утын яру; *колка сахара*—шикәр вату.

**КО'ЛКИЙ** — 1. ярылучан, тиз ярылучан; ватылучан; *колкие дрова* — тиз ярылучан утын; 2. чәнчүчән, кадалучан; *колкая хвоя* — кадалучан ылыс; 3. *перен.* чәнчүле, әче, зәһәр; *колкие слова* — чәнчүле сүзләр, әче сүзләр.

**КО'ЛКОСТЬ** *ж.* — 1. зәһәрлек, чәнчүчәнлек; *колкость замечаний* — искәртүләрнең зәһәрлеге; 2. зәһәр сүз, зәһәр көлү, чәнчүле сүз, чәнчүле көлү; *сказать кому-нибудь колкость* — кемгә дә булса зәһәр сүз әйтү.

**КОЛЛАБОРАЦИОНИ'СТ** *м. книж. презрит.* — коллаборационист (икенче бөтендөнья сугышы чорында фашист гаскәрләре оккупациясе вакытында үз ватанына хыянәт итеп фашистик оккупантларга булышкан кеше).

**КОЛЛЕ'ГА** *ж.* — коллега, иптәш, юлдаш (укудагы яки хезмәттәге иптәш).

**КОЛЛЕГИА'ЛЬНО** *нареч.* — бергәләп, коллегиаль рәвештә; *решить вопрос коллегиально* — мәсьәләне бергәләп чишү, коллегиаль рәвештә чишү.

**КОЛЛЕГИА'ЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет — коллегиальлек, мәсьәләләрне бергәләп хәл итү; *здесь нарушен принцип коллегиальности* — биредә мәсьәләләрне бергәләп хәл итү принцибы бозылган.

**КОЛЛЕГИА'ЛЬНЫЙ** — бергәләп...; *коллегиальное решение вопроса* — мәсьәләне бергәләп чишү; 2. бергәләп эш итүчән; *он человек коллегиальный* — ул бергәләп эш итүчән кеше.

**КОЛЛЕ'ГИЯ** *ж.* — коллегия (1. *устар.* учреждение хезмәтчеләренең барлык составы; 2. Россиядә XVIII йөздә дәүләтнең үзәк учреждениеләре исеме; 3. берничә кеше составында төзелгән һәм киңәшү яки карар чыгару органын тәшкил итә торган группа, мәсәлән, *коллегия Министерства просвещения* — Мәгариф министрлыгы коллегиясе; 4. *устар.* кайбер уку йортларының исеме).

**КОЛЛЕ'ДЖ** *м.* — колледж (Англиядә, АКШ та һ. б. кайбер илләрдә урта яки югары уку йорты).

**КОЛЛЕКТИ'В** *м.* — коллектив (уртак максатны күздә тотучы һәм уртак эш башкаручы кешеләр группасы, берләшмәсе).

**КОЛЛЕКТИВИЗА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет — коллективлаштыру; коллективлашу.

**КОЛЛЕКТИВИЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.* — коллективлаштыру; *коллективизировать сельское хозяйство* — авыл хуҗалыгын коллективлаштыру.

**КОЛЛЕКТИВИЗИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. страд.* — коллективлаштырылу.

**КОЛЛЕКТИВИ'ЗМ** *м. мн.* нет — коллективизм, гомумилек принцибы, коллектив нигез.

**КОЛЛЕКТИВИ'СТ** *м.* — коллективист, коллективизм тарафдары.

**КОЛЛЕКТИ'ВНО** *нареч.* — бергәләп, коллектив белән; *работать коллективно* — бергәләп эшләү, коллектив белән эшләү.

**КОЛЛЕКТИ'ВНОСТЬ** *ж.* — коллективлык, күмәклек, уртаклык, гомумилек.

**КОЛЛЕКТИ'ВНЫЙ** — 1. коллектив...; гомуми, уртак, күмәк, коллектив белән эшләнгән; *коллективный труд* — коллектив хезмәт; *коллективное выступление* — күмәк төстәге чыгыш; 3. коллектив өчен гомуми, коллектив рәвештә...; *коллектив-*

*ное снабжение* — коллектив рәвештә тәэмин итү. ◇ **Коллективный договор** — коллектив договор. **Коллективное хозяйство** — коллектив хуҗалык, колхоз.

**КОЛЛЕ'КТОР** *м.* — коллектор (1. төрле трубалардан килгән сыекчаларны, газларны җыеп, кая булса да җибәрү өчен канал яки зур труба; 2. *физ. тех.* диномомашинада алмаш токны даими токка әйләндерү цилиндры; 3. *спец.* зур издательствоның китапханәләргә китаплар тарату эше белән шөгыльләнә торган бүлеге; 4. тәрбиясез калган балаларны җыеп, балалар йортларына тарату учреждениесе).

**КОЛЛЕКЦИОНЕ'Р** *м. книж.* — коллекционер (коллекцияләр җыючы, сирәк табыла торган әйберләр җыючы).

**КОЛЛЕКЦИОНЕ'РСТВО** *ср. мн.* нет, *книж.* — коллекционерлык (коллекцияләр җыю белән шөгыльләнү; коллекцияләр җыюга һәвәскәрлек).

**КОЛЛЕКЦИОНИ'РОВАТЬ** *несов.* — коллекцияләр җыю.

**КОЛЛЕКЦИОНИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд.* — коллекцияләр җыелу.

**КОЛЛЕ'КЦИЯ** *ж.* — коллекция (гыйльми, әдәби яки тарихи әһәмияте булган бер төрдәге әйберләрнең билгеле бер системада тупланган җыелмасы).

**КОЛЛИ'ЗИЯ** *ж. книж.* — коллизия (капма-каршы көчләрнең, омтылышларның, интересларның бәрелеше).

**КОЛЛО'ДИЙ, КОЛЛО'ДИУМ** *м. мн.* нет, *хим.* — коллодий (медицинада һәм фотографиядә кулланыла торган куе ябышкак эремә).

**КОЛЛО'ИД** *м. хим.* — коллоид (суда эреткәч куе ябышкак эремә бирә һәм кристаллашмый торган матдә).

**КОЛЛОИДА'ЛЬНЫЙ** *хим.* — коллоидсыман.

**КОЛЛО'ИДНЫЙ** *хим.* — коллоид ...-ы; *коллоидный раствор* — коллоид эремәсе.

**КОЛЛО'КВИУМ** *м.* — коллоквиум (укучыларның белемнәрен сынау өчен укытучының алар белән беседа үткәрүе — имтиханның бер төре).

**КО'ЛО** *ср. нескл. истор. полит.* — коло (патша Россиясенең Дәүләт думасында, Австрия һәм Германия парламентларында поляк милләтче партияләренең берләшмәләре).

**КОЛОБА'ШКА** *ж. обл.* — 1. к. колобок; 2 йомры кисәк.

**КОЛОБО'К** *м. обл.* — кабартма, кечкенә түгәрәк икмәк.

**КОЛОБРО'ДИТЬ** *несов. простореч.* — 1. *(возиться)* ыгы-зыгы килү, кайнашу, шаулау; 2. шаяру; *дети колобродят* — балалар шаяралар; 3. *(бесцельно шататься)* тик йөрү, буталып йөрү, бушка йөрү; 4. зиһенне туплый алмау, таралу; *мысли колобродят* — фикерләрем тарала.

**КОЛОВОРО'Т** *м.* — 1. коловорот, борау; 2. *обл.* чоңгыл (су бөтерелеп тора торган урын); 3. *перен. книж. устар.* өермә; *коловорот событий* — вакыйгалар өермәсе.

**КОЛОВРА'ТКА** *ж. зоол.* — әйләнчек (бик кечкенә суалчан).

**КОЛОВРА'ТНЫЙ** *книж.* — 1. *спец.* әйләнмә, әйләнә торган; *коловратное движение* — әйләнмә хәрәкәт; 2. *перен. устар.* үзгәрүчән, ышанычсыз, тотрыксыз; *коловратная судьба* — үзгәрүчән язмыш.

**КОЛОВРАЩЕ'НИЕ** *ср. книж. устар.* — к. круговорот 2.

**КОЛО'ДА** I *ж.* — 1. *(обрубок)* түмәр, бүкән, кискә; 2. улак, ялгаш; *водопойная колода* — су эчерү улагы; 3. ишек башы (ишекнең өске борысы). ◇ **Через пень колоду валить** *простореч.* — „миннән киткәнче, иясенә җиткәнче" дип эшләү, аннан-моннан гына эшләү, эштер-өштер эшләү.

**КОЛО'ДА** II *ж.* — колода (уен карталарының тулы комплекты).

**КОЛО'ДЕЗНЫЙ** — кое...-ы; *колодезная вода* — кое суы.

**КОЛО'ДЕЗЬ** *м. устар.*, **КОЛО'ДЕЦ** *м.* — 1. кое; 2. *тех.* чокыр (аерым техник максатлар өчен хезмәт итә торган чокыр, мәсәлән, *минный колодец* — мина кую чокыры).

**КОЛО'ДКА** *ж.* — 1. *сапож.* аяк киеме калыбы; 2. кыса; *колодка щётки* — щётка кысасы; 3. *истор.* агач богау; 4. кечкенә бүкән (түмәр, кискә).

**КОЛО'ДНИК** *м.*, **КОЛО'ДНИЦА** *ж.* *устар.* — агач богаулы тоткын.

**КОЛО'К** I *м.* — 1. *обл.* кечкенә казык; 2. боргыч; *колки скрипки* — скрипка боргычлары.

**КОЛО'К** II *м. обл.* — кечкенә урман.

**КО'ЛОКОЛ** *м.* — 1. кыңгырау, чаң; 2. *тех.* калпак; *водолазный колокол* — водолаз калпагы. ◇ **Колокола льют** *устар.* — бу хәбәр ялган, бу хәбәр дөрес түгел (гайбәт дигән мәгънәдә).

**КОЛОКО'ЛЕНКА** *ж.* — кечкенә чиркәү манарасы.

**КОЛОКО'ЛЬНЫЙ** — кыңгырау...-ы; чаң кагу...-ы; *колокольный звон* — кыңгырау тавышы, чаң кагу тавышы.

**КОЛОКО'ЛЬНЯ** *ж.* — чиркәү манарасы. ◇ **Со своей колокольни смотреть** — үз күзлегеннән карау, үз аршынына үлчәү.

**КОЛОКО'ЛЬЧИК** *м.* — 1. кечкенә кыңгырау; 2. *бот.* кыңгырау чәчәк.

**КОЛОМА'ЗЬ** *ж. мн.* нет, *обл. спец.* — арба мае, көпчәк мае.

**КОЛО'МЕНСКАЯ ВЕРСТА'** — к. верста.

**КОЛОМЯ'НКА, КАЛАМЯ'НКА, КАЛАМЕ'НКА** *ж. мн.* нет, *спец.* — җитен тукыма.

**КОЛОМЯ'НКОВЫЙ** — җитен тукымадан тегелгән.

**КОЛОНИА'ЛЬНЫЙ** — 1. колониаль, колонияләр...-ы; *колониальный вопрос* — колониаль мәсьәлә, колонияләр мәсьәләсе; 2. колония биләүче...; *колониальные государства* — колония биләүче дәүләтләр.

**КОЛОНИЗА'ТОР** *м.* — колонизатор (1. колонияләрдәге хезмәт ияләре массаларын коллыкка төшерүче империалист; 2. икенче бер илдән яки өлкәдән күчеп килүчеләрне буш җирләргә урнаштыручы, колонизация оештыручы).

**КОЛОНИЗА'ТОРСКИЙ** — 1. колонизаторлык...-ы; *колонизаторские действия* — колонизаторлык хәрәкәтләре; 2. к. колонизационный.

**КОЛОНИЗАЦИО'ННЫЙ** — колонизацияләү...-ы; колонияләштерү...-ы, колонизацион; *колонизационная политика* — колонизацияләү политикасы.

**КОЛОНИЗА'ЦИЯ** *ж.* — к. колонизировать, колонизироваться.

**КОЛОНИЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.* — колонизацияләү, колониягә әверелдерү (1. империалистик дәүләтнең берәр илне, өлкәне басып алып үз колониясенә әверелдерүе; 2. басып алынган илдә колонияләр оештыру; 3. берәр дәүләтнең үз территориясенең читләрендәге буш яткан җирләргә халык урнаштыруы).

**КОЛОНИЗИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. страд.* — колонизацияләнү, колониягә әверелдерелү.

**КОЛОНИЗО'ВАННЫЙ** — колонияләштерелгән.

**КОЛОНИЗОВА'ТЬ** *сов.* и *несов.* — к. колонизировать.

**КОЛОНИЗОВА'ТЬСЯ** *сов.* и *несов.* — к. колонизироваться.

**КОЛОНИ'СТ** *м.*, **КОЛОНИ'СТКА** *ж.* — колонист, колонистка (1. башка илдән, башка өлкәдән күчеп килгән кеше; 2. колониядә яшәүче кеше).

**КОЛО'НИЯ** *ж.* — колония (1. империалистик дәүләт тарафыннан басып алынган, политик, экономик һ. б. яктан эксплуатацияләнә, изелә торган ил яки өлкә; 2. бер дәүләт җиреннән икенче дәүләт җиренә күчеп утырган кешеләр; 3. чит шәһәрдә, чит илдә яшәүче якташлар группасы; 4. махсус максатларны күздә тотып, мәсәлән, аерым группа кешеләрне дәвалау, тәрбияләү, төзәтү максатларын күздә тотып, оештырылган бергә яшәү урыны; *колония глухонемых* — чукрак-телсезләр колониясе; 5. *перен. зоол.* бергә укмашып яшәүчеләр төркеме; *колония микробов* — микроблар колониясе).

**КОЛО'НКА** *ж.* — 1. колонка (а. ванна янына су җылыту өчен куела торган цилиндр формасындагы казан; б. автотранспортка сыек ягулык бирү өчен ясалган махсус җайланма; в. урамда водопроводтан су алу өчен ясалган кран); 2. багана; *газета в пять колонок* — биш баганалы газета; 3. өем; *колонка кирпичей* — кирпечләр өеме.

**КОЛО'ННА** *ж.* — колонна (1. бер-бер артлы тезелеп баскан яки хәрәкәтләнә торган кешеләр яки предметлар төркеме; 2. *архит.* колонна, багана (терәк булып хезмәт итә торган зур багана); 3. өем; *кирпичи сложены в колонны* — кирпечләр өемнәргә өелгән.

**КОЛОННА'ДА** *ж. архит.* — колонналар тезмәсе.

**КОЛО'ННЫЙ** — 1. колонна...-ы; *колонная форма* — колонна формасы; 2 колонналы; *колонный зал* — колонналы зал.

**КОЛОНО'К** *м. зоол.* — Себер көзәне (җәнлек).

**КОЛОНТИ'ТУЛ** *м. тип.* — колонтитул (китап битенең югарыгы башына басылган сүзләр).

**КОЛОНЦИ'ФРА** *ж. тип.* — колонцифра (китап битләренә куела торган цифрлар).

**КОЛОРАТУ'РА** *ж. мн.* нет, *муз.* — колоратура (1. вокаль партияне техник яктан кыен булган тавыш калтыратулар, моңнар белән бизәү; 2. техник яктан кыенлаштырылган вокаль партияне җырлауга сәләтлелек).

**КОЛОРАТУ'РНЫЙ** *муз.* — колоратура ...-ы; *колоратурная техника* — колоратура техникасы; 2. колоратуралы; *колоратурное сопрано* — колоратуралы сопрано.

**КОЛОРИ'СТ** *м.* — колорист (1. *живоп.* үзенең әсәрләрендә, мәсәлән, картиналарында, гравюраларында, орнаментларында, буяуларның ачыклыгы, матурлыгы белән аерылып тора торган художник; 2. *спец.* ситсы буяу фабрикасында буяуларны хәзерләү һәм аларны тукымага төшерү эше белән шөгыльләнүче мастер).

**КОЛОРИ'Т** *м.* — 1. *живоп.* колорит (сәнгать әсәрләрендә, мәсәлән, картинада, гравюрада, орнаментта һ. б., буяуларның тон һәм төс тулылыгы ягыннан бер-берсенә мөнәсәбәтләре); 2. *перен. книж.* төс, колорит; *рассказчик придал этому событию юмористический колорит* — хикәяләүче бу вакыйгага юмористик төс биргән.

**КОЛОРИ'ТНЫЙ** — 1. *живоп.* ачык колоритлы; 2. *перен. книж.* характерлы, үзенә бер төрле, үзенчәлекле; *колоритный старик* — үзенчәлекле карт.

**КО'ЛОС** *м.* (*мн.* колосья) *бот.* — башак, баш.

**КОЛОСИ'СТЫЙ** — зур башаклы, эре башаклы, эре башлы (иген).

**КОЛОСИ'ТЬСЯ** *несов.* — башаклану, башак чыгару, баш чыгару, баш кысу.

**КОЛОСНИ'К** *м. спец.* — 1. рәшәткә (һава керсен һәм көл коелып төшсен өчен мич төбенә куела торган чуен рәшәткә); 2. сәндерә (колмак, көлтә кебекләрне элеп яки өеп киптерү өчен колгалардан аратала ясалган сәндерә).

**КОЛОСНИКИ'** *мн.* — колосниклар (театрда сәхнәнең декорацияләрен югарыдан беркетеп кую өчен хезмәт итә торган рәшәткәле агачлар).

**КОЛО'СС** *м. книж.* — 1. (*устар.* колосс бик зур статуя яки бик зур багана); 2. гаять зур әйбер, гаять мәһабәт әйбер; *колосс мысли* — бик зур фикер иясе. ◇ **Колосс на глиняных ногах** *книж.* — тыштан мәһабәт, эчтән черек.

**КОЛОССА'ЛЬНО** *нареч.* — чиктән тыш зур, гаять зур.

**КОЛОССА'ЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет — үтә зурлык, ифрат зурлык.

**КОЛОССА'ЛЬНЫЙ** — үтә зур, ифрат зур; бик күп; *колоссальное усилие* — бик күп көч кую.

**КОЛОТИ'ТЬ** *несов.* — 1. сугу, шакылдату, кагу; *колотить в дверь* — ишек кагу, ишек шакылдату; 2. бәләкләү, тукмаклау;

*колотить бельё* — кер бәләкләү; 3. талку; *колотить лён* — житен талку; 4. кыйнау, тукмау, дөмбәсләү, төю; *колотить животных* — хайваннарны кыйнау; 5. вату; *колотить посуду* — савыт-саба вату; 6. калтырату; *его колотит лихорадка* — аны бизгәк калтырата.

**КОЛОТИ'ТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. ватылу; *посуда колотится* — савыт-саба ватыла; 2. бәрелү; *колотиться головой об стену* — баш белән стенага бәрелү; 3. шакылдау; *зубы колотятся от холода* — тешләр салкыннан шакылдыйлар; 4. дөп-дөп тибү; *сердце колотится* — йөрәк дөп-дөп тибә; 5. *(перебиваться в нужде) простореч.* — җәфа чигү; 6. *обл.* шакылдату; *колотиться в дверь* — ишек шакылдату, ишек шаку.

**КОЛОТО'ВКА** *ж. обл.* — 1. *спец.* пешкәк, калак (мәсәлән, май язу, камыр изү өчен); 2. *обл.* җәнҗалчы, бәйләнчек хатын-кыз; 3. су тегермәне (ятма чарыклы кечкенә тегермән).

**КОЛОТУ'ШКА** *ж.* — 1. *спец. (деревянный молоток)* тукмак, төйгеч; 2. *простореч. (удар кулаком)* тукмау, йодрык белән сугу; 3. *обл. (у ночных сторожей)* шакылдавык.

**КО'ЛОТЫЙ** — 1. ярылган, тураклаңган; *колотые дрова* — ярылган утын; 2. ватылган, кисәкле; *колотый сахар* — ватылган шикәр, кисәкле шикәр; 3. чәнчүдән булган: *колотая рана* — чәнчүдән булган яра.

**КОЛО'ТЬ** *несов.* — 1. яру; тураклау; *колоть дрова* — утын яру; 2. вату; *колоть сахар* — шикәр вату; *колоть лёд* — боз вату; 3. чәнчү, кадау; *колоть штыком* — штык белән чәнчү; 4. *безл.* чәнчешү; *мне грудь колет* — минем күкрәгем чәнчешә; 5. сую, чалу, бугазлау; *колоть овцу* — сарык сую; 6. *перен.* битәрләү, кыерсыту, мыскыллау, чәнчүле сүзләр әйтү; *за что вы меня то и дело колете?* — ни өчен сез мине һаман битәрлисез? ◇ **Колоть глаза** — битәрләү, оялту. **Правда глаза колет** — туры әйткән туганына ярамаган.

**КОЛОТЬЁ** *ср. мн.* нет, *разг.* — чәнчешү, чәнчү алу; *колотьё в груди* — күкрәк чәнчешү.

**КОЛО'ТЬСЯ** *несов.* — 1. ярылу; ватылу; *дрова колются* — утын ярыла; *сахар колется* — шикәр ватыла: 2. чәнчү, кадау; *ёж колется* — керпе чәнчи.

**КОЛО'ША** *ж. тех.* — колоша (домна мичендә берьюлы тутырыла торган руданың һәм ягулыкның билгеле микъдары).

**КОЛОШЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — баш кысу, баш чыгару.

**КОЛОШМА'ТИТЬ** *несов. простореч.* — тукмау, дөмбәсләү (кыйнау).

**КОЛОШНИ'К** *м. тех.* — колошник (домна мичененң руда һәм ягулык тутыру өчен хезмәт итә торган югарыгы өлеше һәм авызы).

**КОЛПА'К** *м.* — 1. калфак; 2. *(покрышка)* капкач, япкыч; 3. *перен. разг. фам. (о простаке)* ачык авыз.

**КОЛПА'ЧИТЬ** *несов. простореч.* — *к.* околпачивать.

**КОЛПА'ЧНЫЙ** — калфак...-ы, калпак...-ы; *колпачные побрякушки* — калфакка тагыла торган вак-төякләр.

**КОЛПАЧО'К** *м.* — 1. кечкенә калфак, такыя; 2. кечкенә капкач.

**КОЛТУ'Н** *м. мед.* — чәч киезләнү (авыру).

**КОЛТЫХА'ТЬ** *несов. обл.* — чайкалдыру, чайпалдыру, селкетү; *колтыхать лодку* — көймәне чайкалдыру, селкетү.

**КОЛТЫХА'ТЬСЯ** *несов. обл.* — чайкалу, чайпалу, селкенү.

**КОЛТЫХНУ'ТЬ** *сов. однокр. обл.* — чайпалдырып кую, селкетеп кую.

**КОЛТЫХНУ'ТЬСЯ** *сов. однокр. обл.* — чайпалып кую, селкенеп кую, чайпалып китү, селкенеп китү.

**КОЛУМБА'РИЙ** *м. спец.* — колумбарий (крематорийда яндырылган мәетләрнең көле салынган тартмаларны саклау урыны).

**КОЛУ'Н** *м.* — авыр балта, утын яру балтасы, колун.

**КОЛУПА'ТЬ** *несов. простореч.* — куптару, чокып алу (мәсәлән, икмәк катысын).

**КОЛУПНУ'ТЬ** *сов. однокр. простореч.* — куптарып алу.

**КОЛХО'З** *м.* — колхоз, коллектив хуҗалык.

**КОЛХО'ЗНИК** *м.* — колхозчы.

**КОЛХО'ЗНИЦА** *ж.* — колхозчы хатын-кыз.

**КОЛХО'ЗНЫЙ** — колхоз...-ы; *колхозный рынок* — колхоз базары; *колхозное строительство* — колхоз төзелеше.

**КОЛЧА'Н** *м. истор.* — ук савыты, ук кынысы.

**КОЛЧЕДА'Н** *м. мин.* — колчедан, кәлчегән.

**КОЛЧЕНО'ГИЙ** *обл.* — аксак, чатан.

**КОЛЫБЕ'ЛЬ** *ж.* — 1. бишек, бәллү; 2. *перен.* бишек, ватан; *СССР — колыбель мировой революции* — СССР — бөтендөнья революциясенең бишеге (ватаны). ◇ **С колыбели** *книж.* — туган көненнән үк, кече яшьтән үк.

**КОЛЫБЕ'ЛЬКА** *ж. разг.* — кечкенә бишек, кечкенә бәллү.

**КОЛЫБЕ'ЛЬНЫЙ** *книж.* — бишек ...-ы; *колыбельная песня* — бишек җыры.

**КОЛЫМА'ГА** *ж. устар.* — ком арбасы, таш арбасы; зур авыр арба.

**КОЛЫХА'НЬЕ** *ср. мн.* нет — тирбәтү; тирбәлү; селкенү; селкетү; чайкалу; чайкалдыру.

**КОЛЫХА'ТЬ** *несов.* — тирбәтү, селкетү, тирбәлдерү, чайкалдыру, җилфердәтү.

**КОЛЫХА'ТЬСЯ** *несов.* — тирбәлү, селкенү, чайкалу, җилфердәү.

**КОЛЫХНУ'ТЬ** *сов. однокр.* — тирбәтеп кую, селкетеп кую.

**КОЛЫХНУ'ТЬСЯ** *сов. однокр.* — тирбәлеп кую, селкенеп кую.

**КО'ЛЫШЕК** *м.* — кечкенә казык.

**КОЛЬ** — *к.* коли. ◇ **Коль скоро** *книж. устар.* — әгәр...-а икән; *коль скоро вы согласитесь, я готов примириться* — әгәр сез риза буласыз икән, мин татулашырга әзер.

**КОЛЬДКРЕ'М** *м.* — кольдкрем (тирене йомшарту өчен биткә, кулга сөртә торган май).

**КОЛЬЕ'** *ср. нескл.* — муенса.

**КОЛЬНУ'ТЬ** *сов. однокр.* — 1. чәнчеп алу, кадап алу; 2. кинәт чәнчү алу; 3. сую, чалу (хайванны); 4. *перен.* чәнечкеле сүз әйтеп кую.

**КОЛЬРА'БИ** *ж. нескл. бот.* — кольраби, шалкан кәбестә (кәбестәнең бер төре).

**КОЛЬТ** *м. спец.* — кольт (револьвер һәм пулемётның бер төре).

**КОЛЬЦЕВА'НИЕ** *ср. спец.* — 1. *с.-х.* боҗралау, балдаклау (корткычлар үрмәләп менүдән саклау өчен агачның кәүсәсен сумала яки башка берәр нәрсә белән боҗралап буяу); 2. боҗра кидерү, балдак кидерү (төрле фәнни тикшеренүләр алып барганда даими күзәтчелек итәргә мөмкинлек булсын өчен кошларның аякларына, балыкларның койрыгына боҗра кидерү).

**КОЛЬЦЕВА'ТЬ** *сов.* и *несов. спец.* — к. кольцевание.

**КОЛЬЦЕВИ'ДНЫЙ** *книж.* — боҗрасыман, балдаксыман.

**КОЛЬЦЕВО'Й** *книж.* — 1. боҗра ...-ы, балдак...-ы; *кольцевое отверстие* — боҗра тишеге; 2. *спец.* әйләнмә; *кольцевое движение* — әйләнмә хәрәкәт.

**КОЛЬЦЕОБРА'ЗНЫЙ** — к. кольцевидный.

**КОЛЬЦО'** *ср.* — 1. боҗра, балдак; 2. боҗрасыман, балдаксыман әйбер. ◇ **Годичное кольцо** — яшь сызыгы (агач кәүсәсендә ел саен барлыкка килеп, аның ничә ел үскәнен күрсәтә торган түгәрәк катлам). **Согнуться кольцом** *разг. перен.* — ялагайланып баш ию.

**КО'ЛЬЧАТЫЙ** — 1. боҗралардан тора торган; *кольчатая цепочка* — боҗралардан тора торган чылбыр; 2. *бот.* боҗрабоҗра булып...; *кольчатое расположение листьев* — яфракларның боҗра-боҗра булып урнашуы; 3. боҗралы, балдаклы; *кольчатые черви* — боҗра(лы) суалчаннар.

**КОЛЬЧУ'ГА** *ж. истор.* — кольчуга (вак металл боҗралардан эшләнгән борынгы сугыш киеме).

**КОЛЬЧУ'ЖНЫЙ** *спец.* — 1. кольчуга...-ы; *кольчужный рукав* — кольчуга җиңе; 2. к. кольчатый 1.

**КОЛЮ'ЧЕСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. чәнчүчәнлек, кадалучанлык; 2. *перен.* чәнчүлелек, зәһәрлек; *колючесть насмешки* — мәсхәрәләп көлүнең зәһәрлеге.

**КОЛЮ'ЧИЙ** — чәнечкеле; *колючая проволока* — чәнечкеле тимерчыбык; 2. чәнчә торган, кадала торган; чеметтереп ала торган; *колючий мороз* — чеметтереп ала торган суык; 3. *перен.* агулы, зәһәр, чәнчүле, ачы; *колючий язык* — чәнчүле тел, ачы тел.

**КОЛЮ'ЧКА** *ж.* — чәнечке, инә, шырпы; *колючка чертополоха* — шайтан таягының чәнечкесе (инәсе, шырпысы).

**КО'ЛЮШКА** *ж. зоол.* — чәнечкеле балык.

**КОЛЯ'СКА** *ж.* — 1. сиртмәле арба; 2. балалар арбасы, коляска.

**КОМ** *м.* (*мн.* комья) — 1. кантар, төер, кисәк; *ком снега* — кар кисәге; 2. *перен.* төер, авырлык; *ком на груди лежит* — күкрәгемдә төер бар. ◇ **Свернуться комом** — бөгәрләнеп яту.

**КО'МА** *ж. мн.* нет, *мед.* — кома (организм агуланудан булган хәлсезлек).

**КОМА'НДА** *ж.* — 1. *воен.* команда, боерык; *раздалась команда* — команда яңгырады; 2. команда; *сапёрная команда* — сапёрлар командасы; *футбольная команда* — футбол командасы; 3. *разг. фам. шутл.* — төркем; *в комнату ввалилась весёлая команда* — бүлмәгә шат кешеләр төркеме килеп керде. ◇ **Принять команду** — командирлыкны кабул итү, үз өстеңә алу. **Быть под командой строгого начальника** — таләпчән начальник командалыгы астында булу.

**КОМАНДА'РМ** *м. воен.* — командарм, армия командующие.

**КОМАНДИ'Р** *м. воен. мор.* — командир.

**КОМАНДИРОВА'ТЬ** *сов.* и *несов.* — командировкага җибәрү.

**КОМАНДИРОВА'ТЬСЯ** *сов.* и *несов. страд.* — командировкага җибәрелү.

**КОМАНДИРО'ВКА** *ж.* — 1. *только ед.* командировкага җибәрү; 2. командировка; *получить командировку* — командировка алу; 3. *разг. канц.* командировка кәгазе; *напишите мне командировку* — миңа командировка кәгазе языгыз.

**КОМАНДИРО'ВОЧНЫЙ** — 1. командировка...-ы; *командировочное удостоверение* — командировка таныклыгы; 2. *разг. только мн. в знач. сущ.* командировка акчасы; *я получил командировочные* — мин командировка акчасы алдым.

**КОМАНДИ'РСКИЙ** — командирлык ...-ы; командирлар...-ы; *командирские обязанности* — командирлык бурычлары; *командирская комната* — командирлар бүлмәсе.

**КОМАНДИ'РША** *ж. разг. фам.* — 1. командир хатыны; 2. *перен.* власть яратучан, өстенлек итәргә яратучан хатын.

**КОМА'НДНЫЙ** — 1. команда ...-ы; боерык...-ы; *командные слова* — команда (боерык) сүзләре; 2. командирлар...-ы; *командные курсы* — командирлар курсы; *командный состав* — командирлар составы; 3. командирлык...-ы; *командная должность* — командирлык вазифасы; 4. *перен.* өстен, өстенлек итүче; *занять командное положение* — өстен урын алу, өстенлек алу. ◇ **Командные высоты** — 1. *воен.* иң биек урыннар (тирә-юньгә караганда биегрәк һәм гаскәрнең эш итүе өчен уңай урын); 2. иң мөһим участок, иң кирәкле пункт (халык хуҗалыгында, иҗтимагый-политик көрәштә). **Командные состязания** *спорт.* — командалар ярышы (спортның берәр төрендә беренчелекне алу өчен командалар арасында алып барыла торган ярышлар).

**КОМА'НДОВАНИЕ** *ср. мн.* нет — 1. к. командовать; 2. *собир. воен.* командирлар составы, гаскәр башлыклары, командова-

ние; *командование полка* — полкның командирлар составы.

**КОМА'НДОВАТЬ** *несов.* — 1. команда бирү; 2. командовать итү, җитәкчелек итү; *командовать полком* — полк белән командовать итү, полкка җитәкчелек итү; 3. *перен.* боерык биреп тору; *привык дома командовать* — өендә боерык биреп торырга күнеккән; 4. *спец.* өстенлек итү; *высота, командующая над местностью* — әйләнә-тирәгә өстенлек итүче биеклек (ягъни: әйләнә-тирәдәге иң биек урын).

**КОМАНДО'Р** *м.* — командор (1. *истор.* рыцарьлар союзларында югары дәрәҗә; 2. спорт оешмаларында башлык; 3. авиация отрядының начальнигы; 4. *мор.* борынгы заманда флотта адмиралдан түбәнрәк дәрәҗә).

**КОМАНДО'РСКИЙ** — командорлык...-ы, командор...-ы; *командорское звание* — командорлык званиесе; *командорский значок* — командор значогы.

**КОМА'НДУЮЩИЙ** — командующий (зур гаскәри берләшмә начальнигы); *командующий армией* — армия командующие.

**КОМА'Р** *м. зоол.* — озынборын, озынаяк. ◇ **Комар носа не подточет** — менә дигән, менә дигән итеп эшләнгән, тел тидермәслек.

**КОМАРИ'НЫЙ** — 1. озынборын...-ы; *комариный укус* — озынборын тешләве; 2. *перен.* бик кечкенә, үтә кечкенә; *комариная порция* — бик кечкенә порция.

**КОМБА'ЙН** *м. тех.* — комбайн.

**КОМБА'ЙНЕР** *м. тех.* — комбайнчы.

**КОМБА'ЙНОВЫЙ** *тех.* — комбайн белән...; *комбайновая уборка хлеба* — игенне комбайн белән урып-җыю.

**КОМБЕ'Д** *м. истор.* — ярлылар комитеты.

**КОМБИНА'Т** *м.* — комбинат (1. *экон.* төрле производство тармакларына караган промышленность предприятиеләренең берләшмәсе; 2. *педаг.* төрле баскыч уку йортларының берләшмәсе).

**КОМБИНА'ТОР** *м.* — комбинатор (комбинацияләр һәвәскәре, комбинацияләр ясый белүче).

**КОМБИНАТО'РНЫЙ** *науч.* — комбинатор...; *комбинаторный анализ в математике* — математикада комбинатор анализ.

**КОМБИНАЦИО'ННЫЙ** — 1. комбинацион, комбинацияләргә нигезләнгән; 2. комбинацияләргә оста; *комбинационный ум* — комбинацияләргә оста акыл.

**КОМБИНА'ЦИЯ** *ж.* — комбинация (1. күбесенчә бер төрдән булган предметларның үзара билгеле бер тәртиптә урнашуы, берләшүе, кушылуы; 2. *экон.* бер төрдәге предприятиеләрне берләштерү юлы белән производствоны концентрацияләү процессы; 3. *перен.* берәр нәрсәгә ирешү теләге белән эшләнгән алымнар системасы, катлаулы план; 4. хатын-кыз эчке бельёсының бер төре; балалар җәйге костюмының бер төре).

**КОМБИНЕЗО'Н** *м. спец.* — комбинезон (курткасы белән чалбары тоташ итеп тегелгән эш киеме).

**КОМБИНИ'РОВАННЫЙ** — катнаш, комбинациядән тора торган; *комбинированный метод* — катнаш метод.

**КОМБИНИ'РОВАТЬ** *несов.* — 1. кушу, катнаштыру, берләштерү; *комбинировать цветы для изящного букета* — матур букет килеп чыксын өчен төрле төстәге чәчәкләрне кушу; 2. төрлечә исәпләп карау; төрлечә эшләп карау; *он всячески комбинировал, как бы подешевле приобрести шубу* — туннЫ ничек тә арзангарак сатып алу өчен ул төрлечә исәпләп карады.

**КОМБИНИ'РОВАТЬСЯ** *несов.* — 1. кушылу, берләшү, укмашу; 2. *страд.* берләштерелү, укмаштырылу.

**КОМБРИ'Г** *м.* — комбриг (бригада командиры).

**КОМВУ'З** *м.* — комвуз (коммунистик югары уку йорты).

**КОМДИ'В** *м.* — комдив (дивизия командиры).

**КОМЕДИА'НТ** *м.* — 1. *устар.* артист, актёр; 2. *истор. театр.* комедиант (циркта, балаганда көлкеле рольләрне башкаручы артист); 3. *перен.* икейөзле кеше, монафыйк.

**КОМЕДИА'НТСКИЙ** — комедиантлык...-ы; *комедиантский вид* — комедиантлык кыяфәте.

**КОМЕДИА'НТСТВО** *ср. мн.* нет — икейөзлелек, монафыйклык.

**КОМЕДИ'ЙНЫЙ** — комедия...-ы; *комедийный стиль* — комедия стиле.

**КОМЕ'ДИЯ** *ж.* — комедия (1. *лит. театр* көлкеле һәм күңелле эчтәлекле драматик әсәр; 2. *устар.* комедияләр куя торган театр; 3. һәртөрле көлке вакыйга). ◇ **Ломать комедию, разыгрывать комедию** *перен. разг. фам.* — икейөзләләнү, монафыйклану.

**КОМЕ'ДЬ** *ж. простореч. фам.* — кәмит, көлке вакыйга. ◇ **Что ты комедь ломаешь?** — нәрсә син икейөзләләнәсең?

**КО'МЕЛЬ** *м. обл.* — 1. аскы өлеш, аскы оч (үсемлек сабагының, чәчнең, мөгезнең, каурыйның тамырга тоташкан аскы өлеше); 2. агачның, бүрәнәнең юан башы, төп башы.

**КОМЕНДА'НТ** *м. офиц.* — комендант (1. *воен.* хәрби крепость яки ныгытылган район начальнигы; 2. гарнизонда хезмәтнең дөрес алып барылуын, дисциплина һәм тәртип саклауны күзәтеп торучы гаскәри начальник; 3. хөкүмәт йортлары, тулай тораклар һ. б. башлыгы).

**КОМЕНДА'НТСКИЙ** — комендант ...-ы; *комендантский приказ* — комендант приказы.

**КОМЕНДАТУ'РА** *ж. офиц.* — комендатура (1. комендантның эш бинасы һәм канцеляриясе; 2. *канц. устар.* комендантлык вазифасы).

**КОМЕНДО'Р** *м. мор.* — комендор (диңгез флоты тупчысы).

**КОМЕ'ТА** *ж. астр.* — комета, койрыклы йолдыз.

**КОМЕ'ТНЫЙ** — комета ...-ы; *кометное сияние* — комета балкышы.

**КО'МИ** *нескл.* — коми халкы, комилар.

**КОМИ'ЗМ** *м. мн.* нет — көлкелек; *комизм игры актёра* — актёр уйнавының көлкелеге.

**КО'МИК** *м.* — 1. комик (а. көлке рольләрне башкара торган артист; б. *устар.* комедия әсәрләре язучы); 2. *разг.* мәзәк кеше, мәзәкчел кеше.

**КОМИССА'Р** *м.* — комиссар (политик, административ яки хуҗалык эшләрен үтәргә хөкүмәт тарафыннан аерым полномочие бирелгән җаваплы кеше).

**КОМИССАРИА'Т** *м. офиц.* — комиссариат (башында комиссар торган учреждение).

**КОМИССАРИА'ТСКИЙ** — комиссариат ...-ы; *комиссариатское имущество* — комиссариат милке.

**КОМИССА'РСКИЙ** — комиссарлык ...-ы; комиссарлар...-ы; *комиссарские обязанности* — комиссарлык бурычлары.

**КОМИССА'РСТВО** *ср. мн.* нет, *разг.* — комиссарлык.

**КОМИССИОНЕ'Р** *м. торг.* — комиссионер (сәүдә эшләрендә, сәүдә килешүләрендә арадашлык итүче).

**КОМИССИОНЕ'РСКИЙ** *торг.* — комиссионерлык...-ы; *комиссионерские обязанности* — комиссионерлык бурычлары.

**КОМИССИОНЕ'РСТВО** *ср. мн.* нет, *торг.* — комиссионерлык.

**КОМИССИОНЕ'РСТВОВАТЬ** *несов. разг. торг.* — комиссионерлык итү, комиссионерлык белән шөгыльләнү.

**КОМИССИО'ННЫЙ** *торг.* — 1. комиссиягә бирелгән; *комиссионные товары* — комиссиягә бирелгән товарлар; 2. комиссионный (комиссиягә бирелгән товарлар сата торган магазин).

**КОМИ'ССИЯ** I *ж.* — комиссия (1. *офиц.* нинди дә булса махсус мәсьәләләрне чишү, башкару өчен берәр учреждение яки оешма карамагында берничә кешедән оештырылган вакытлы яки даими орган; 2. *торг.* билгеле күләмдә акча түләү шарты белән башкарыла торган йомыш, эш).

**КОМИ'ССИЯ** II *ж. перен. разг. шутл.* — мәшәкать, кыенлык, бәла; *ну, уж комиссия же с вами!* (Достоевский) — ну, сезнең белән мәшәкать тә соң инде!

**КОМИТЕ'Т** *м.* — комитет.

**КОМИТЕ'ТСКИЙ** — комитет ...-ы; *комитетские дела* — комитет эшләре.

**КОМИТЕ'ТЧИК** *м. разг.* — комитет члены.

**КОМИ'ЧЕСКИЙ** — 1. көлкеле, көлдергеч; *комическая роль* — көлкеле роль; 2. көлке; *комическая история* — көлке вакыйга; 3. комиклык...-ы; *комический талант* — комиклык таланты. ◇ **Комический актёр** — комик (көлкеле рольләрне башкара торган артист).

**КОМИ'ЧНО** *нареч.* — көлке итеп; *он очень комично рассказывал об этом приключении* — бу мажара турында ул бик көлке итеп сөйли торган иде.

**КОМИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет — көлкелек.

**КОМИ'ЧНЫЙ** *разг.* — көлке; *комичная история* — көлке вакыйга.

**КО'МКАТЬ** *несов. разг.* — 1. йомарлау, йомарлап укмаштыру; *комкать бумагу* — кәгазьне йомарлап укмаштыру; 2. *перен. фам.* ашык-пошык кыскартып бозу; *комкать лекцию* — лекцияне ашык-пошык кыскартып бозу.

**КО'МЛЕВЫЙ: комлевый конец** — төп башы, юан башы, юан очы (агач, бүрәнә, каурый һәм мөгезгә карата гына әйтелә).

**КОММЕНТА'РИЙ** *м. книж.* — комментарий, текстка аңлатма, ачыклама, шәрех.

**КОММЕНТА'ТОР** *м. книж.* — комментатор, аңлатма бирүче, шәрехләүче.

**КОММЕНТИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. книж.* — аңлатма бирү, комментарий бирү, шәрехләү.

**КОММЕНТИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд. книж.* — аңлатма бирелү, шәрехләнү, комментарий бирелү.

**КОММЕРСА'НТ** *м.* — коммерсант, эре сәүдәгәр.

**КОММЕ'РЦИЯ** *ж. мн.* нет, *торг.* — коммерция, сәүдә, сәүдә эшләре. ◇ **Поддержать коммерцию** *разг. шутл.* — сатучыга сәүдә булсын өчен аннан берәр нәрсә сатып алу.

**КОММЕ'РЧЕСКИЙ** — коммерция...-ы; сәүдә...-ы; *вести коммерческие дела* — коммерция (сәүдә) эшләре алып бару; *коммерческий пароход* — сәүдә пароходы.

**КО'ММИ** *м. нескл. устар.* — приказчик, магазин хезмәтчесе.

**КОММИВОЯЖЁР** *м. доревол.* и *загр.* — коммивояжёр (берәр сәүдә, промышленность предприятиесенең товар үрнәкләрен күрсәтеп йөреп заказлар җыю эшен башкаручы агент).

**КОММУ'НА** *ж.* — коммуна (1. милек һәм хезмәтнең уртаклыгы нигезендә бергә яшәү өчен берләшкән кешеләр коллективы; шундый коллективның яши торган җире; 2. Көнбатыш Европаның кайбер илләрендә административ-территориаль берәмлек исеме). ◇ **Парижская коммуна** — Париж коммунасы (1871 нче елның 18 мартында властьны үз кулларына алган Париж эшчеләренең революцион хөкүмәте).

**КОММУНА'ЛЬНИК** *м.* — коммунальник (коммуналь хуҗалык органнары хезмәткәре һәм эшчесе).

**КОММУНА'ЛЬНЫЙ** — коммуналь; *коммунальное хозяйство* — коммуналь хуҗалык.

**КОММУНА'Р** *м. истор.* — коммунар (1. Париж коммунасына катнашкан кеше; 2. берәр коммунаның члены).

**КОММУНИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *полит.* — коммунизм (пролетариат революциясенең җиңүе һәм пролетариат диктатурасы урнаштыру нәтиҗәсендә капитализмга алмашка килә торган иҗтимагый строй); *социализм — первая фаза коммунизма* — социализм — коммунизмның беренче фазасы.

**КОММУНИКАТИ'ВНЫЙ** *науч.* — фикерләрне тапшыру ...-ы, фикерләрне белдерү ...-ы; *слово есть коммуникативное*

*средство* — сүз — фикерләрне тапшыру чарасы ул.

**КОММУНИКАЦИО'ННЫЙ** — коммуникация...-ы, бәйләныш...-ы, элемтә...-ы; *коммуникационная линия* — элемтә линиясе.

**КОММУНИКА'ЦИЯ** *ж.* — 1. *спец.* коммуникация, бәйләныш, элемтә; 2. *науч.* фикерләрне тапшыру, фикерләрне белдерү.

**КОММУНИ'СТ** *м.* — коммунист (коммунистлар партиясе члены).

**КОММУНИСТИ'ЧЕСКИЙ** — коммунистик, коммунистлар...-ы; *коммунистическое движение* — коммунистик хәрәкәт; *коммунистическая партия* — коммунистлар партиясе.

**КОММУНИ'СТКА** *ж.* — коммунистка (к. коммунист).

**КОММУТА'ТОР** *м. тех. физ.* — коммутатор (электр тогы үтә торган линияне тоташтыру һәм өзү, шулай ук токның юнәлешен үзгәртү приборы).

**КОММУТАЦИО'ННЫЙ** *тех. физ.* — коммутация...-ы; *коммутационная доска* — коммутация тактасы.

**КОММУТА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *тех. физ.* — коммутация (алмаш электр тогын даими токка әйләндерү).

**КОММЮНИКЕ'** *ср. нескл. полит.* — коммюнике (дәүләтләр арасында алып барылган сөйләшүләр, төзелгән килешүләр турында хөкүмәтнең рәсми белдерүе).

**КО'МНАТА** *ж.* — бүлмә. ◇ **Меблированные комнаты** *устар.* — кечкенә гостиница.

**КО'МНАТНЫЙ** — бүлмә...-ы; *комнатная температура* — бүлмә температурасы.

**КОМОВО'Й** — кисәкле, кантарлы.

**КОМО'Д** *м.* — комод.

**КОМО'К** *м.* — 1. төер, кечкенә кисәк; *комок грязи* — пычрак кисәге; 2. бөтәрләнгән кисәк, йомарланган кисәк. ◇ **Свернуться, съёжиться в комок** — бөгәрләнеп яту.

**КОМО'ЛЫЙ** — мүкләк, мөгезсез; *комолая корова* — мүкләк сыер.

**КОМПА'КТНОСТЬ** *м. мн.* нет, *книж.* — тыгызлык, җыйнаклык.

**КОМПА'КТНЫЙ** — компакт, тыгыз, җыйнак, тыгыз укмашкан, тыгыз береккән.

**КОМПАНЕ'ЙСКИЙ** *просторен.* — 1. аралашучан, компаниячел; *компанейский человек* — компаниячел кеше; 2. акча салышып оештырыла торган (мәсәлән, мәҗлес).

**КОМПА'НИЯ** *ж.* — 1. компания, төркем; 2. компания, ширкәт (капиталистик сәүдә яки промышленность ширкәте); *экспортная компания* — экспорт компаниясе (ширкәте). ◇ **Водить с кем-н. компанию** — кем белән дә булса аралашу. **Поддержать компанию** *разг.* — иптәшләр тарафыннан уйланган берәр эштә катнашуга риза булу.

**КОМПАНЬО'Н** *м.* — 1. *торг. дореволь.* компаньон, ширкәттә катнашучы; 2. *разг.* иптәш, мәҗлестәш.

**КОМПАНЬО'НКА** *ж.* — к. компаньон.

**КОМПА'РТИЯ** *ж.* (Коммунистическая партия) — компартия (Коммунистлар партиясе).

**КО'МПАС** *м. физ.* — компас (дөньяның дүрт ягын билгеләүдә кулланыла торган прибор).

**КО'МПАСНЫЙ** *физ.* — компас...-ы; *компасное показание* — компас күрсәтүе.

**КОМПАТРИО'Т** *м.*, **КОМПАТРИО'ТКА** *ж. разг. устар.* — ватандаш.

**КОМПА'УНД** *м. тех.* — компаунд (ике цилиндрлы махсус системалы пар машинасы).

**КОМПЕ'НДИЙ** *м.*, **КОМПЕ'НДИУМ** *м. науч.* — компендиум (берәр фәннең кыскача эчтәлеге).

**КОМПЕНСАЦИО'ННЫЙ** *спец. книж.* — компенсация...-ы; *компенсационная сумма* — компенсация суммасы.

**КОМПЕНСА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет — компенсация (1. *книж.* түләү, каплау; *компенсация убытков* — зарарларны каплау; 2. *мед.* элекке хәленә кайтару; *компенсация сердца* — йөрәкнең эшләвен элекке хәленә кайтару; 3. *тех.* төгәл механизмның дөрес эшләвенә комачаулый торган тышкы тәэсирләрне бетерү).

**КОМПЕНСИ'РОВАННЫЙ** — 1. компенсация рәвешендә бирелгән, түләнгән; 2. *мед.* элекке хәленә кайтарылган.

**КОМПЕНСИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. книж. спец.* — 1. компенсация рәвешендә бирү, түләү; 2. *мед.* элекке хәленә кайтару.

**КОМПЕНСИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. страд. книж. спец.* — компенсация рәвешендә бирелү, түләнү; 2. *мед.* элекке хәленә кайтарылу.

**КОМПЕТЕ'НТНО** *нареч.* — нигезле, төпле, белеп; *компетентно судить о чём-л.* — берәр нәрсә турында төпле фикер йөртү.

**КОМПЕТЕ'НТНОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. нигезлелек, төплелек; *компетентность суждения* — фикер йөртүнең нигезлелеге; 2. хәбәрдарлык; белемлелек; *компетентность в вопросах политики* — политика мәсьәләләрендә хәбәрдарлык.

**КОМПЕТЕ'НТНЫЙ** *книж.* — 1. хәбәрдар, белемле; *компетентный врач* — хәбәрдар врач; 2. нигезле, төпле, авторитетлы; *компетентное мнение* — нигезле фикер; 3. *право* тулы хокуклы; *я сам юридически компетентное лицо* — мин үзем юридик яктан тулы хокуклы кеше.

**КОМПЕТЕ'НЦИЯ** *ж. мн.* нет, *книж.* — компетенция (1. берәр кешенең яхшы хәбәрдар булган, нигезле һәм тирән белгән мәсьәләләре; *это не входит в мою компетенцию* — бу минем компетенциямә керми (ягъни, мин бу мәсьәләне ныклап белмим); 2. *право* учреждение яки аерым кешенең эш йөртүгә хакы булган мәсьәләләре, өлкәсе, мәйданы).

**КОМПИЛИ'РОВАТЬ** *несов. книж.* — компиляцияләү, компиляция ясау (башка авторлар тарафыннан язылган әсәрләрдән чүпләп берәр нәрсә язу).

**КОМПИЛИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд.* — компиляцияләнү, компиляция ясалу.

**КОМПИЛЯТИ'ВНЫЙ** *книж.* — компилятив, компиляция юлы белән төзелгән, компиляциягә нигезләнгән.

**КОМПИЛЯ'ТОР** *м.* — компилятор, компиляция белән шөгыльләнүче.

**КОМПИЛЯ'ЦИЯ** *ж. книж.* — компиляция (1. башка авторларның әсәрләреннән чүпләп төзелгән әсәр; 2. шундый әсәрне төзү).

**КО'МПЛЕКС** *м.* — комплекс (нинди дә булса предметларның, күренешләрнең яки үзенчәлекләрнең җыелмасы).

**КО'МПЛЕКСНЫЙ** *книж.*—1. комплекс...; *комплексное соединение* — комплекс кушылма; 2. комплекслы; *комплексная бригада* — комплекслы бригада.

**КОМПЛЕ'КТ** *м.* — 1. комплект (билгеле бер максатка хезмәт итә торган инструментлар, кисәкләр, детальләр, әйберләр җыелмасы); *комплект журналов за 1950 год* — 1950 нче елда чыккан журналларның комплекты; 2. *офиц.* чик сан (берәр җиргә алына, урнаштырыла торган кешеләрнең чик саны); *комплект пассажиров на пароходе* — пароходтагы пассажирларның чик саны.

**КОМПЛЕКТА'ТОР** *м. спец.* — комплектатор, туплаучы, комплектовать итүче.

**КОМПЛЕКТОВА'ТЬ** *несов. спец.*—1. туплау, комплектовать итү, комплектка тутыру, тиешле санына җиткерү; *комплектовать состав служащих* — хезмәткәрләр составын туплау; 2. комплект төзү; *комплектовать журналы* — журналлар комплектын төзү.

**КОМПЛЕКТОВА'ТЬСЯ** *несов. страд. спец.* — туплану, комплектовать ителү, комплектка тутырылу, тиешле санына җиткерелү.

**КОМПЛЕ'КЦИЯ** *ж. разг.* — комплекция, тән төзелеше.

**КОМПЛЕМЕ'НТ** *м.* — комплемент (1. *науч.* өстәмә, өстәү, тутыру; 2. *мед.* сәламәт хайваннарның канында булган, аларны йогышлы авырулардан саклый торган матдә).

**КОМПЛИМЕ'НТ** *м.* — комплимент, мактау сүзе, мактаулы сүз.

**КОМПЛИМЕ'НТЩИК** *м. просторечн.* — комплиментчы (һәрвакыт мактаулы сүзләр әйтергә яратучы).

**КОМПЛО'Т** *м. книж.* — җинаятьчел сүз куешу, җинаятьчел союз (берәр кешегә каршы).

**КОМПОЗИ'ТОР** *м.* — композитор (музыка әсәрләре авторы).

**КОМПОЗИ'ТОРСКИЙ** — композитор...-ы, композиторлык...-ы; *композиторский талант* — композиторлык таланты.

**КОМПОЗИ'ТОРСТВОВАТЬ** *несов. разг.*— композитор булу, музыкаль әсәрләр язу.

**КОМПОЗИ'ТОРША** *ж. разг.* — *к.* композитор.

**КОМПОЗИЦИО'ННЫЙ**—композиция...-ы, композицион; *композиционная техника* — композиция техникасы; *композиционное строение* — композицион төзелеш.

**КОМПОЗИ'ЦИЯ** *ж. книж.* — композиция (1. *муз.* музыка әсәрләре төзү теориясе; 2. *архит.* архитектура теориясенең кисәкләрне бер бөтенгә җыю турындагы бүлеге; 3. *искус.* әсәрнең художество төзелеше; 4. берәр нәрсәнең состав кисәкләренең җыелмасы, төрле матдәләрнең эретмәсе; 5. *устар.* имитация, охшатып эшләнгән әйбер).

**КОМПОНЕ'НТ** *м. книж.* — компонент, состав элемент, состав кисәк.

**КОМПОНОВА'ТЬ** *несов.* — төзү, әзерләү (аерым кисәкләрдән, элементлардан); *компоновать научную статью* — гыйльми мәкалә төзү; *компоновать очередной номер журнала* — журналның чираттагы номерын әзерләү.

**КОМПОНОВА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — төзелү.

**КОМПО'СТ** *м. с.-х.* — компост (төрле үсемлек ташландыкларын черетеп хәзерләнгән ашлама, җир ашламасы).

**КОМПО'СТЕР** *м.* — компостер (билетка, пломбага һ. б. тишеп яки сытып билге салу өчен кулланыла торган келәшчәсыман прибор).

**КОМПОСТИ'РОВАТЬ** *несов. ж.-д.*— компостер белән билге салу, компостировать итү.

**КОМПОСТИ'РОВАТЬСЯ** I *несов. страд.*— компостер белән билге салыну, компостировать ителү.

**КОМПОСТИ'РОВАТЬСЯ** II *сов.* и *несов. с.-х.* — череп бетү (компост ясау өчен өелгән өемдә).

**КОМПО'СТНЫЙ** *с.-х.* — компост...-ы; *компостная яма* — компост чокыры.

**КОМПО'Т** *м.* — компот (төрле җимешләрне шикәрле суда кайнатып ясалган сыек ашамлык).

**КОМПРЕ'СС** *м.* — компресс (авырткан урынга куела торган юеш бәйләвеч).

**КОМПРЕ'ССНЫЙ** — компресс...-ы; *компрессная клеёнка* — компресс клеёнкасы.

**КОМПРЕ'ССОР** *м.* — компрессор (1. *тех.* һаваны яки башка газны кысу машинасы; 2. *мед.* операция вакытында кан тамырын кысып тоту өчен кулланыла торган прибор).

**КОМПРЕ'ССОРНЫЙ** *спец.* — компрессор...-ы; *компрессорный завод* —компрессор заводы.

**КОМПРОМЕТА'НТНЫЙ** *разг. устар.* — оятлы итә торган, яман атлы итә торган.

**КОМПРОМЕТА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *книж. устар.* — к. компрометировать.

**КОМПРОМЕТИ'РОВАТЬ** *несов. книж.* — оятлы итү, яман атлы итү; уңайсыз хәлдә калдыру, яман атын чыгару.

**КОМПРОМЕТИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд.* — оятлы ителү, яман атлы ителү; уңайсыз хәлдә калдырылу.

**КОМПРОМИ'СС** *м. книж.* — компромисс, килешү, юл куешып килешү (берберенең омтылышлары, интереслары төрлечә булганда).

**КОМПРОМИ'ССНЫЙ** — компромисслы; *компромиссное предложение* — компромисслы тәкъдим.

**КОМСОМО'Л** *м.* — комсомол (коммунистик яшьләр союзы).

**КОМСОМО'ЛЕЦ** *м.* — комсомолец

**КОМСОМО'ЛКА** *ж.* — комсомолка.

**КОМСОМО'ЛЬСКИЙ** — 1. комсомол...-ы; *комсомольский билет* — комсомол билеты; 2. комсомоллар...-ы; *комсомольское собрание* — комсомоллар җыелышы.

**КОМСОСТА'В** *м.* — командирлар составы, комсостав, командирлар.

**КОМФО'РКА** *ж.* — к. конфорка.

**КОМФО'РТ** *м. мн.* нет — комфорт (көнкүреш өчен тудырылган уңайлыклар җыелмасы).

**КОМФОРТА'БЕЛЬНЫЙ, КОМФО'РТНЫЙ** — көнкүреш өчен уңайлы, комфортлы.

**КОМФРА'КЦИЯ** *ж.* — коммунистлар фракциясе.

**КОМЧВА'НСТВО** *ср. мн.* нет — комчванство, коммунистмын дип борын күтәрү.

**КОН** *м.* — кон (1. кузна, чүрәкәй һ. б. ш. уеннардааткый барып төшәргә тиеш урын; 2. акчалы отыш уенында акча салына торган урын; 3. карта, шахмат һ. б. ш. уеннарның бер партиясе).

**КОНА'РМИЯ** *ж.* — атлы армия (гаскәр).

**КОНА'ТЬСЯ** *несов. обл.* — 1. тотышу, шобага салу; 2. узышу, ярышу, көрәшү.

**КОНВЕ'ЙЕР** *м. тех.* — конвейер (өзлексез хәрәкәт итеп йөкләрне, аерым әйберләрне күчереп тора торган тасма).

**КОНВЕЙЕРИЗА'ЦИЯ** *ж. тех.* — к. конвейеризировать и конвейеризироваться.

**КОНВЕЙЕРИЗИ'РОВАННЫЙ** — конвейерлаштырылган, конвейер белән эш итә торган.

**КОНВЕЙЕРИЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. тех.* — конвейерлаштыру, конвейер белән тәэмин итү.

**КОНВЕЙЕРИЗИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. страд. тех.* — конвейерлаштырылу, конвейер белән кораллandырылу.

**КОНВЕЙЕРИЗО'ВАННЫЙ** — к. конвейеризированный.

**КОНВЕЙЕРИЗОВА'ТЬ** *сов.* и *несов. тех.* — к. конвейеризировать.

**КОНВЕЙЕРИЗОВА'ТЬСЯ** *сов.* и *несов. тех.* — к. конвейеризироваться.

**КОНВЕ'ЙЕРНЫЙ** *тех.* — конвейер...-ы; *конвейерная система* — конвейер системасы.

**КОНВЕ'ЙЕРЩИК** *м. спец.* — конвейерчы, конвейерны эшләтүче.

**КОНВЕ'НТ** *м. истор.* — конвент (кайбер илләрдә конституция төзү яки аны үзгәртү өчен чакырыла торган дәүләт вәкилләре җыелышы, киңәшмәсе). ◇ Национальный конвент — милли конвент (1792 нче елда француз буржуаз революциясе вакытында король төшерелгәннән соң гомуми сайлау тәртибендә сайланган вәкилләр җыелышы).

**КОНВЕНЦИОНА'ЛЬНЫЙ** *науч.* — шартлы.

**КОНВЕНЦИО'ННЫЙ** — конвенцион, конвенция белән билгеләнгән, аерым килешү буенча эшләнгән.

**КОНВЕ'НЦИЯ** *ж. дипл.* — конвенция, договор, килешү (нинди дә булса специаль техник мәсьәлә буенча төзелгән халыкара договор).

**КОНВЕРГЕ'НЦИЯ** *ж.* — конвергенция (1. бер-беренә бәйле булмаган төрле күренешләрнең аерым сыйфатлар ягыннан үзара охшашлыгы; 2. *биол.* төрле организмнардагы кайбер үзенчәлекләрнең кардәшлек нәтиҗәсе буларак түгел, бәлки башка сәбәпләр аркасында охшашлыгы).

**КОНВЕ'РСИЯ** *ж. экон.* — конверсия (дәүләт заёмы шартларының үзгәртелүе, мәсәлән, проценты кимetelү, түләү вакыты озайтылу һ. б.).

**КОНВЕ'РТ** *м.* — конверт, пакет.

**КОНВЕРТИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. экон.* — конверсия ясау.

**КОНВЕРТИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. страд. экон.* — конверсия ясалу.

**КОНВЕ'РТНЫЙ** *спец.* — конверт...-ы; *конвертная бумага* — конверт кәгазе.

**КОНВОИ'Р** *м.* — конвоир (1. тоткыннарны, әсирләрне саклап озатучы кеше; 2. сәүдә пароходларын дошманнан саклап озата торган пароход яки самолёт).

**КОНВОИ'РОВАТЬ** *несов. офиц.* — сакчы сыйфатында озата бару, саклап озата бару (мәсәлән, әсирләрне, тоткыннарны).

**КОНВОИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд. офиц.* — конвой белән озатылу, сак астында озатылу.

**КОНВО'Й** *м.* — конвой (1. тоткыннарны, әсирләрне саклап озата баручы отряд; 2. сәүдә пароходларын дошманнан саклап озата бара торган пароходлар яки самолётлар).

**КОНВО'ЙНЫЙ** — 1. сакчы; *конвойное судно* — сакчы пароход; 2. *в знач. сущ.* к. конвоир.

**КОНВУЛЬСИ'ВНЫЙ** *мед.* — көзән җыерулы; *конвульсивное движение* — көзән җыерулы хәрәкәт.

**КОНВУ'ЛЬСИЯ** *ж. мед.* — көзән җыеру.

**КОНГЕНИА'ЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — охшашлык, бердәйлек, туры килүчәнлек (рухы, акылы, таланты ягыннан).

**КОНГЕНИА'ЛЬНЫЙ** — конгениаль, бердәй, охшаш, якын, туры килә торган; *перевод, конгениальный оригиналу* — оригиналга якын тәрҗемә, оригиналга туры килә торган тәрҗемә.

**КОНГЛОМЕРА'Т** *м. книж.* — конгломерат (1. төрле кисәкләрнең һәм әйберләрнең системасыз кушылмасы; *это не теория, а просто конгломерат различных мнений* — бу теория түгел, бәлки төрле фикерләрнең системасыз кушылмасы гына; 2. *геол.* төрле-төрле аерым кисәкләрдән укмашкан тау токымы).

**КОНГРЕ'СС** *м. книж.* — конгресс (1. съезд; 2. *полит.* Америкада һәм кайбер бүтән илләрдә закон чыгару органы).

**КОНДАЧКА'**: с кондачка — өстән-өстән генә, эштер-өштер генә, аңламастан; *решать дело с кондачка* — мәсьәләне өстән-өстән генә чишү.

**КОНДЕНСА'ТОР** *м.* — конденсатор (1. *физ.* электр туплау приборы; 2. *тех.* парны сыекчага әйләндерү приборы).

**КОНДЕНСАЦИО'ННЫЙ** — конденсацион, конденсация юлы белән алынган; *конденсационная вода* — конденсация юлы белән алынган су, парны куерту юлы белән хасил булган су.

**КОНДЕНСА'ЦИЯ** *ж. спец.* — к. конденсировать и конденсироваться.

**КОНДЕНСИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. тех.* — 1. куерту; *конденсировать молоко* — сөтне куерту; 2. туплау, жыю; *конденсировать энергию* — энергия (электр энергиясе) туплау, жыю; 3. сыекчага әйләндерү; *конденсировать пар* — парны сыекчага әйләндерү.

**КОНДЕНСИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. тех.* — 1. куеру; 2. *страд.* куертылу; 3. тупланy, жыелу; 4. сыекчага әверелү; 5. *страд.* сыекчага әвереллерелү.

**КОНДИ'ТЕР** *м. устар.* — кондитер (1. татлы ашамлыклар хәзерләү остасы; 2. *дорев.* и *загр.* кондитер магазины хуҗасы; 3. берәр кешенең туе яки юбилее уңае белән үзенең өендә яки хуҗаның өенә чакырылып тантаналы аш мәҗлесе оештыручы кеше).

**КОНДИ'ТЕРСКАЯ** *ж.* — татлы ашамлыклар магазины, кондитер әйберләре магазины, кондитерский магазин.

**КОНДИ'ТЕРСКИЙ** — 1. татлы ашамлыклар хәзерләү...-ы, татлы ашамлыклар сату...-ы; *кондитерская фабрика* — татлы ашамлыклар хәзерләү фабрикасы; *кондитерский магазин* — татлы ашамлыклар сату магазины; 2. кондитерский (өйдә хәзерләнмәгән); *кондитерский торт* — кондитерский торт.

**КОНДИЦИО'ННЫЙ** *спец.* — кондицион, килешү договорында күрсәтелгән, килешү шартлары белән билгеләнгән.

**КОНДИ'ЦИЯ** *ж. устар.* — кондиция (1. договорның, килешүнең шарты; 2. *только мн. истор.* вакытлыча читкә китеп, хосусый рәвештә өйгә йөреп укытучылык итү эше).

**КОНДОВО'Й, КО'НДОВЫЙ** *обл.* — 1. *спец.* таза үзагачлы, нык үзагачлы (агач); *кондовый кедр* — таза үзагачлы эрбет агачы; 2. нык; *кондовые люди* — нык кешеләр.

**КОНДОМИ'НИУМ** *м. право* — кондоминиум (ике яки берничә дәүләтнең берәр территорияне бергәләп биләүләре).

**КО'НДОР** *м. зоол.* — кондор (Көньяк Америкала иң эре ерткыч кош).

**КОНДРА'ШКА** *м. мн.* нет, *простореч. фам.* — кинәт үлем; *его хватил кондрашка* — ул кинәт үлеп китте.

**КОНДУИ'Т** *м. истор.* — кондуит (укучыларның яки гаскәриләрнең үзләрен тотуда булган җитешсезлекләре языла торган журнал).

**КОНДУ'КТОР** I *м.* — кондуктор (тимер юл вагоннарында тәртипне, чисталыкны күзәтүче, пассажирларга хезмәт күрсәтүче; трамвайларда билет сатучы, тәртипне күзәтеп торучы).

**КОНДУ'КТОР** II *м.* — кондуктор (1. металл кисә торган станокта кискечкә дөрес юнәлеш бирә торган прибор; 2. электр үткәргеч).

**КОНДУ'КТОРНЫЙ** *тех.* — кондукторлы, электр үткәргечле; *кондукторная машина* — кондукторлы машина.

**КОНДУ'КТОРСКИЙ** — кондукторлык...-ы, кондукторлар...-ы; *кондукторская бригада* — кондукторлар бригадасы.

**КОНЕВО'Д** *м. спец.* — ат үрчетүче.

**КОНЕВО'ДСТВО** *ср. мн.* нет, *с.-х.* — ат үрчетүчелек.

**КОНЕВО'ДЧЕСКИЙ** *с.-х.* — ат үрчетү...-ы; *коневодческий совхоз* — ат үрчетү совхозы.

**КОНЁК** *м.* — 1. кечкенә ат; 2. *обл.* өй түбәсе бизәге (ат башына охшатып ясалган агач бизәк); 3. *чаще мн.* тимераяк, коньки. ◇ **Это — его конёк** — бу аның яраткан нәрсәсе (сөйләүгә, омтылышка карата әйтелә).

**КОНЕСОВХО'З** *м.* (коневодческий совхоз) — ат үрчетү совхозы.

**КОНЕ'Ц** *м.* — 1. оч; *конец палки* — таяк очы; *конец верёвки* — бау очы; 2. азак, ахыр; *конец года* — ел ахыры; *к концу дня* — көн азагына таба; 3. ахыр, соңгы өлеш; *конец романа написан плохо* — романның ахыры (соңгы өлеше) начар язылган; 4. *разг.* үлем; *тут ему и конец пришёл* — шунда аңа үлем дә килеп житте. ◇ **И дело с концом** *разг.* — шуның белән эш тә бетте. **Конца нет** *разг.* — очы-кырые юк, иге-чиге юк. **Без конца** — бик күп, иге-чиге юк, бик озак. **Конца-краю нет** — иге-чиге юк. **Один конец** *простореч.* — барыбер үләсе. **В конец** или **до конца** — беткәнче, бөтенләйгә. **Из конца в конец** — бер башыннан икенче башына, аркылыга-буйга. **В конце концов** — ахыр чиктә, ниһаять, бара торгач. **На худой конец** — иң начар булганда, һич тә булмаса. **Под конец** *разг.* — ахырда, ниһаять. **Со всех концов** — һәр яктан. **Сводить концы с концами** — ничек кирәк алай җиткерү, тартып-сузып кына житкерү (акчаны). **Хоронить концы** *простореч.* — эзен яшерү. **И концы в воду** — эзе дә калмас, эзе дә калмады. **Палка о двух концах** — таяк ике башлы, таякның ике очы бар. **За оба конца взял один рубль** — барып кайту өчен бер сум алды. **Отмахать пешком этакий конец** — шундый зур араны җәяү бару.

**КОНЕ'ЧНО** — 1. *ввод. сл.* шиксез, әлбәттә, билгеле; 2. *утверд. частица* әйе, әлбәттә.

**КОНЕ'ЧНОСТЬ** *ж.* — 1. *анат.* кул-аяк, очлык; 2. *только ед. редко* мәңге түгеллек, чиклелек; *конечность жизни* — тормышның мәңге түгеллеге.

**КОНЕ'ЧНЫЙ** — 1. чикле; *жизнь человека конечна* — кешенең тормышы чикле; 2. читтәге, ахыргы, соңгы, актыкки, азакки; *конечный дом на этой улице* — бу урамдагы актыкки өй; *конечная цель* — актыккы максат, ахыргы максат; 3. төп, нигездә ята торган; *конечная причина* — төп сәбәп. ◇ **В конечном счёте** — ахыр чиктә.

[конечный] — ... очлы; *остроконечный* — үткен очлы.

**КО'НИК** *м. обл.* — 1. кечкенә ат; 2. ян сәке.

**КОНИ'НА** *ж. мн.* нет — ат ите, елкы ите.

**КОНИ'ЧЕСКИЙ** — 1. конус...-ы; *коническая форма* — конус формасы; 2. конуссыман, конус формасындагы; *коническая колба* — конуссыман колба.

**КО'НКА** *ж. разг.* — атлы трамвай.

**КОНКОРДА'Т** *м. полит.* — конкордат (Рим папасының нинди дә булса берәр дәүләт белән договоры).

**КОНКРЕТИЗА'ЦИЯ** *ж. книж.* — к. конкретизировать и конкретизироваться.

**КОНКРЕТИЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. книж.* — конкретлаштыру, ачыклаштыру, ачыклау.

**КОНКРЕТИЗИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. книж.* — 1. конкретлашу, ачыклану, ачыклану; 2. *страд.* конкретлаштырылу, ачыкландырылу.

**КОНКРЕТИЗОВА'ТЬ** *сов.* и *несов. книж.* — к. конкретизировать.

**КОНКРЕ'ТНО** *нареч.* — ачык итеп, анык итеп, конкрет рәвештә.

**КОНКРЕ'ТНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — конкретлык, аныклык, реальлек.

**КОНКРЕ'ТНЫЙ** — конкрет, анык, реаль, билгеле; *приведите хоть один конкретный пример* — бер генә булса да конкрет мисал китерегез әле.

**КОНКУРЕ'НТ** *м.* — конкурент (башка берәү белән конкуренциядә катнашучы).

**КОНКУРЕ'НТКА** *ж.* — конкурентка.

**КОНКУРЕ'НЦИЯ** *ж. мн.* нет — конкуренция (1. капиталистик җәмгыятьтә табышның иң зур өлешен эләктереп алу, товар урнаштыру базарлары, чимал чыганаклары һ. б. өчен капиталистлар арасында бара торган аяусыз, өзлексез көрәш; 2. берәр хезмәт өлкәсендә бер үк максатка ирешергә тырышучылар арасындагы ярыш). ◇ **Вне конкуренции** *разг.* — чагыштыргысыз яхшы; *товар вне конкуренции* — товар чагыштыргысыз яхшы.

**КОНКУРИ'РОВАТЬ** *несов. книж.* — конкуренция алып бару, көрәшү.

**КО'НКУРС** *м.* — конкурс (1. сәнгатьтә, фәндә, спортта алдынгылык өчен көрәш, ярыш; 2. *торг. дореволюц.* күп бурыч калдырып бөлгән кешенең эшен карар өчен бурыч ияләре тарафыннан оештырылган җыелыш).

**КО'НКУРСНЫЙ** — 1. конкурс...-ы; *конкурсные испытания* — конкурс сынаулары; 2. конкурс өчен хәзерләнгән, конкурс өчен язылган; *конкурсное сочинение* — конкурс өчен язылган сочинение.

**КО'ННИЦА** *ж.* — атлы гаскәр, атлы отряд.

**КОННОЗАВО'ДСКИЙ** *спец.* — ат заводы...-ы; *коннозаводское хозяйство* — ат заводы хуҗалыгы.

**КОННОЗАВО'ДСТВО** *ср. спец.* — 1. *только ед.* яхшы токымлы атлар үрчетү; 2. ат заводы.

**КОННОЗАВО'ДЧЕСКИЙ** — к. коннозаводский.

**КО'ННЫЙ** — 1. ат...-ы; *конный завод* — ат заводы; 2. атлы; *конная железная дорога* — атлы тимер юл; *конная армия* — атлы армия.

**КОНОВА'Л** *м.* — 1. *обл.* атлар дәвалаучы имче; 2. *разг. пренебр.* начар, белемсез врач.

**КОНОВО'Д** I *м. разг.* — утаман, башлап йөрүче, җитәкче; *во всяком подобном деле всегда являются зачинщики и коноводы* (Достоевский) — мондый һәрбер эштә һәркайчан башлап җибәрүчеләр һәм утаманнар табыла.

**КОНОВО'Д** II *м. воен.* — коновод (атлар караучы солдат).

**КОНОВО'ДИТЬ** *несов. простореч.* — утаманлык итү, башлап алып бару.

**КО'НОВЯ'ЗЬ** *ж. спец.* — ат бәйләү баганасы.

**КОНОГО'Н** *м. спец.* — коногон (шахталарда вагонеткага җигелгән атларны йөртүче).

**КОНОКРА'Д** *м.* — ат карагы.

**КОНОКРА'ДСТВО** *ср. мн.* нет — ат урлау.

**КОНОПА'ТИТЬ** *несов.* — конопатить итү, мүкләү (тишек, ярык урыннарны сүс, чүбек, мүк кебек әйберләр белән тыгызлап томалау).

**КОНОПА'ТИТЬСЯ** *несов. страд.* — мүкләнү, конопатить ителү.

**КОНОПА'ТКА** *ж. спец.* — 1. к. конопатить; 2. мүкләгеч (корал).

**КОНОПА'ТЧИК** *м.* — мүкләүче.

**КОНОПА'ТЫЙ** *обл.* — 1. сипкелле; 2. шадра (чәчәктән).

**КОНОПЛЯ'** *ж. мн.* нет, *бот.* — киндер, киндераш (үсемлек).

**КОНОПЛЯ'НИК** *м.* — киндер басуы, киндер чәчелгән җир.

**КОНОПЛЯ'НКА** *ж. зоол.* — киндер чыпчыгы.

**КОНОПЛЯ'НЫЙ** — киндер...-ы; *конопляное масло* — киндер мае.

**КО'НОЧНЫЙ** I *разг. устар.* — атлы тимер юл...-ы; *коночные вагоны* — атлы тимер юл вагоннары.

**КО'НОЧНЫЙ** II *обл.* — кондагы; *коночные бабки* — кондагы кузналар.

**КОНСЕКВЕ'НТНЫЙ** *науч.* — эзлекле.

**КОНСЕРВАТИ'ВНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — консервативлык, иске карашлылык.

**КОНСЕРВАТИ'ВНЫЙ** *книж.* — консерватив, иске карашлы, яңалыкка каршы.

**КОНСЕРВАТИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *книж.* — консерватизм (1. консервативлык, иске карашлылык; 2. консерватив карашлар системасы).

**КОНСЕРВА'ТОР** *м.*, **КОНСЕРВА'ТОРКА** *ж.* — консерва́тор, консерва́торка (1. консерватив карашлы кеше; 2. консерваторлар партиясе члены).

**КОНСЕРВАТО'РЕЦ** *м.*, **КОНСЕРВАТО'РКА** *ж. разг.* — консерватория студенты.

**КОНСЕРВАТО'РИЯ** *ж.* — консерватория (югары музыка мәктәбе).

**КОНСЕРВА'ТОРСКИЙ** — консерваторлык...-ы, консерваторлар...-ы; *консерватор-*

*ские взгляды* — консерваторлык карашлары.

**КОНСЕРВАТО'РСКИЙ** — консерватория...-ы; *консерваторское здание* — консерватория бинасы.

**КОНСЕРВА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *книж.*— 1. черүдән саклау; 2. үсешне, эшне әкренәйтү, туктатып тору.

**КОНСЕРВИ'РОВАНИЕ** *ср. мн.* нет, *спец.*— консервка әйләндерү.

**КОНСЕРВИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.*— 1. консервлау, консервка әйләндерү; *консервировать грибы* — гөмбәне консервлау; 2. черүдән саклау, бозылудан саклау (махсус чаралар белән); 3. *перен.* вакытлыча туктату, әкренәйтү (үсешне, хәрәкәтне, эшне).

**КОНСЕРВИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. книж.*— 1. вакытлыча эштән туктау; *элеватор консервировался* — элеватор вакытлыча эштән туктады; 2. *страд.* консервлану; *рыба консервируется в маринаде* — балык маринадта консервлана; 3. *страд.* вакытлыча эштән туктатылу.

**КОНСЕ'РВНЫЙ** — 1. консерв...-ы; *консервная фабрика* — консерв фабрикасы; 2. консерв...-ы; консервтан бушаган; *консервная коробка* — консерв коробкасы; консервтан бушаган коробка.

**КОНСЕ'РВЫ** *ед.* нет — 1. консерв (черүдән, бозылудан саклаwaырлык итеп ябык савытларга тутырылган ашамлык); 2. саклагыч күзлек (бик көчле яктыдан, тузаннан, җилдән).

**КОНСИ'ЛИУМ** *м. мед.*— консилиум (авыручының авыруын һәм аны дәвалау юлларын билгеләү өчен берничә врачның киңәшмәсе).

**КОНСИСТЕ'НЦИЯ** *ж.* — консистенция (сыек һәм каты җисемнәрнең йомшаклык, тыгызлык, катылык, ныклык дәрәҗәсе).

**КО'НСКИЙ** — ат...-ы; *конский волос* — ат кылы.

**КОНСОЛИДА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *книж.*— к. консолидировать.

**КОНСОЛИДИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. книж.* — 1. срогын озайту (кыска сроклы бурыч йөкләмәләренең срогын озайту); 2. консолидацияләү, бергә туплап ныгыту; *консолидировать все силы* — барлык көчләрне бергә туплап ныгыту.

**КОНСОЛИДИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов.*— 1. бергә тупланып ныгу; 2. *страд.* сроклары озайтылу (кыска сроклы бурыч йөкләмәләренең).

**КОНСОМЭ'** *ср. нескл.*— консомэ (шулпаның бер төре).

**КОНСОНА'НС** *м. муз.*— консонанс, аһәң (аккордтагы берничә авазның үзара ярашлылыгы).

**КОНСОНАНТИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *лингв.*— консонантизм (нинди дә булса бер телдәге тартык авазлар системасы).

**КОНСО'РЦИУМ** *м. торг. фин.*— консорциум (нинди дә булса финанс планын, финанс чарасын бергәләп тормышка ашыру өчен берничә капиталистның берләшүе, килешүе).

**КОНСПЕ'КТ** *м. книж.*— конспект (әсәрнең, мәкаләнең, докладның һ. б. кыскача эчтәлеге).

**КОНСПЕКТИ'ВНО** *нареч.* — кыска итеп, кыска гына итеп, конспектив рәвештә.

**КОНСПЕКТИ'ВНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— кыскалык.

**КОНСПЕКТИ'ВНЫЙ** *книж.*— кыска, кыскача, конспект характерындагы; *конспективный обзор последних событий* — соңгы вакыйгаларга кыскача күзәтү.

**КОНСПЕКТИ'РОВАТЬ** *несов. книж.*— конспектлау, конспект төзү.

**КОНСПЕКТИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. страд. книж.*— конспектлану, конспект төзелү.

**КОНСПИРАТИ'ВНО** *нареч.* — яшерен, яшерен рәвештә, яшертен, яшертен рәвештә, астыртын.

**КОНСПИРАТИ'ВНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— конспиративлык, яшеренлек, яшертенлек.

**КОНСПИРАТИ'ВНЫЙ** *полит.*— конспиратив, яшерен, яшертен; *конспиративное совещание* — конспиратив киңәшмә, яшерен киңәшмә.

**КОНСПИРА'ТОР** *м. полит.*— конспиратор, конспирациядә катнашучы.

**КОНСПИРА'ЦИЯ** *ж.* — конспирация (1. *полит.* үзенең эшен сер итеп тоту һәм членнарын яшерү өчен легаль булмаган оешма тарафыннан кулланыла торган методлар; 2. *разг.* астыртынлык, сер итеп саклау).

**КОНСПИРИ'РОВАТЬ** *несов. полит.*— конспирация оештыру, конспирация методларын куллану.

**КОНСТА'НТА** *ж. науч.* — константа (1. үзгәрүчә зурлыклар рәтендә үзгәрмәс зурлык; 2. *физ. хим.* нинди дә булса бер матдәнең даими билгесен күрсәтә торган зурлык, мәсәлән, атом авырлыгы).

**КОНСТА'НТНЫЙ** *науч.*— даими, үзгәрми торган, тотрыклы.

**КОНСТАТА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *книж.*— к. констатировать.

**КОНСТАТИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. книж.*— (берәр нәрсәнең барлыгын) билгеләү, билгеләп үтү, әйтеп үтү, раслау; *констатировать большую успешность учащихся* — укучыларның зур уңышларын билгеләү.

**КОНСТАТИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. страд. книж.*— билгеләнү; раслану.

**КОНСТЕЛЛЯ'ЦИЯ** *ж. книж.*— констелляция (1. *астр.* күктәге яктырткычларның бер-беренә карата торышлары; 2. *перен.* вакыйгаларның бәйләнеше).

**КОНСТИТУИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. книж.*— билгеләү, ачыклау, ачу (составын, эчтәлеген); *конституировать президиум* — президиумның составын билгеләү; *конституировать понятие причинности* — сәбәплелек төшенчәсенең эчтәлеген ачыклау.

**КОНСТИТУИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. книж.*— билгеләнү (составы, эчтәлеге), ачылу.

**КОНСТИТУТИ'ВНЫЙ** *науч.* — төзелеш...-ы, оешу...-ы; структура...-ы; *конститутивные свойства какой-нибудь систе-*

*мы* — нинди дә булса бер системаның төзелеш (оешу) үзенчәлекләре.

**КОНСТИТУЦИОНАЛИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *полит.* — конституционализм (конституцион монархияне урнаштыру һәм аны яклауга омтыла торган буржуаз реакцион юнәлеш).

**КОНСТИТУЦИОНАЛИ'СТ** *м.* — конституционализм тарафдары, конституционалист.

**КОНСТИТУЦИО'ННЫЙ** — 1. конституцион; *конституционный закон* — конституцион закон; 2. конституцион, конституциягә нигезләнгән; *конституционная монархия* — конституцион монархия.

**КОНСТИТУ'ЦИЯ** I *ж. науч.* — төзелеш, структура; *организм слабой конституции* — зәгыйфь төзелешле организм.

**КОНСТИТУ'ЦИЯ** II *ж.* — конституция (дәүләтнең төп законнарының җыелмасы); *конституция СССР* — СССР конституциясе.

**КОНСТРУИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. книж.* — 1. оештыру, төзү; *конструировать правительство* — хөкүмәт оештыру; 2. төзү, планын төзү, конструкциясен төзү; *конструировать машину* — машинаның конструкциясен төзү.

**КОНСТРУИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. книж.* — 1. оештырылу, төзелү; 2. конструкциясе төзелү.

**КОНСТРУКТИВИ'ЗМ** *м. мн.* нет — конструктивизм (сәнгатьтә иң чик формализмны һәм техницизмны алга сөрүче һәм сәнгатьнең идеологик эчтәлеген танымаучы реакцион буржуаз юнәлеш).

**КОНСТРУКТИ'ВНОСТЬ** *ж. мн.* нет — конструкциягә яраклылык.

**КОНСТРУКТИ'ВНЫЙ** — 1. конструктив, конструкциягә караган; *конструктивные недостатки сооружения* — корылманың конструкциягә караган җитешсезлекләре; 2. конструкциягә яраклы; *конструктивный материал* — конструкциягә яраклы материал; 3. *перен.* конструктив, нигез булырга яраклы, уңышлы, файдалы; *конструктивное предложение* — конструктив тәкъдим, нигез булырга яраклы тәкъдим.

**КОНСТРУ'КТОР** *м.* — конструктор (1. берәр конструкциянең авторы; 2. һәртөрле предметлар, корылмалар ясап уйнау өчен кирәкле материаллар салынган ящик — балалар уенчыгы).

**КОНСТРУ'КТОРСКИЙ** — конструкторлык...-ы, конструкторлар...-ы; *конструкторские курсы* — конструкторлар курсы.

**КОНСТРУ'КЦИЯ** *ж.* — конструкция, төзелеш, корылыш, ясалыш (1. берәр корылманың, машинаның төзелеше, аның аерым кисәкләренең үзара урнашулары; 2. берәр сәнгать әсәрендә аерым кисәкләрнең үзара урнашулары, бер-берсенә мөнәсәбәтләре; 3. грамматик бәйләнеш ноктасыннан караганда сөйләмдәге сүзләрнең үзара урнашулары; 4. азмы-күпме катлаулы төзелешле корылыш, машина).

**КО'НСУЛ** *м.* — 1. консул, илче; 2. *истор.* консул (борынгы Рим республикасында, Франциядә иң югары дәрәҗәле дәүләт эшлеклесе).

**КО'НСУЛЬСКИЙ** — консуллык...-ы; *консульское право* — консуллык хокукы.

**КО'НСУЛЬСТВО** *ср.* — 1. *дипл.* консуллык, илчелек (бинасы һәм канцеляриясе); *Советское консульство в Иране* — Иранда Совет консуллыгы; 2. *истор.* консуллык чоры (а. Рим республикасында консул идарә иткән чор; б. Франция тарихында Бонапарт переворотыннан соң аны император итеп игълан иткәнгә кадәр булган чор).

**КО'НСУЛЬСТВОВАТЬ** *несов.* — консул булып эшләү.

**КОНСУЛЬТА'НТ** *м. спец.* — консультант, консультация бирүче.

**КОНСУЛЬТАЦИО'ННЫЙ** *спец.* — консультация...-ы; *консультационное бюро* — консультация бюросы.

**КОНСУЛЬТА'ЦИЯ** *ж. спец.* — консультация (1. берәр мәсьәләне белгеч катнашы белән тикшерү; белгечләр киңәшмәсе; 2. белгечнең берәр мәсьәлә буенча киңәше; 3. *офиц.* аерым мәсьәләләр буенча киңәшләр, күрсәтмәләр бирә торган учреждение; 4. *педаг.* укытучы тарафыннан укучыларга күрсәтелә торган даими ярдәм).

**КОНСУЛЬТИ'РОВАТЬ** *несов. книж.* — 1. консультация алу, киңәшү; *консультировать с юристом по вопросу о нарушении договора* — договорны бозу мәсьәләсе буенча юристтан консультация алу; 2. консультация бирү, киңәш бирү; *консультировать клиенту* — клиентка консультация бирү.

**КОНСУЛЬТИ'РОВАТЬСЯ** *несов. книж.* — консультация алу, киңәш алу.

**КОНТАГИО'ЗНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *мед.* — йогышлылык.

**КОНТАГИО'ЗНЫЙ** *мед.* — йогышлы.

**КОНТА'КТ** *м.* — 1. контакт, кушылу; *контакт двух сплавов* — ике эретмәнең кушылуы; 2. *тех.* контакт (электр үткәргечләрнең тоташкан урыны); 3. *перен.* бәйләнеш, үзара бәйләнеш, контакт; *нашему обществу надо вступить в контакт с этим учреждением* — безнең җәмгыятькә бу учреждение белән контакт ясарга (бәйләнешкә керергә) кирәк.

**КОНТА'КТНЫЙ** *тех.* — 1. контакт...-ы, кушылу...-ы; *контактный процесс* — кушылу процессы; 2. кушылудан барлыкка килгән.

**КОНТЕ'ЙНЕР** *м. спец.* — контейнер (тимер юл платформаларында товар төяп йөртү өчен кулланыла торган стандарт ящик).

**КОНТЕ'КСТ** *м. филол.* — контекст (текстның мәгънә ягыннан бер бөтен булган һәм үзенә кергән сүзнең яки тулы бер фразаның мәгънәсен ачып бирә торган өлеше); *понять незнакомое слово в контексте* — таныш булмаган сүзне контекстта аңлау.

**КОНТИНГЕ'НТ** *м.* — контингент (1. берәр коллективның, учреждениенең, оешманың, предприятиенең, армиянең һ. б. карамагында

булган барлык кешеләр; 2. *экон. торг.* чит дәүләткә чыгарыла яки аннан кертелә торган кайбер товарлар өчен куелган чик, норма).

**КОНТИНГЕНТИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. спец.*— контингентын билгеләү.

**КОНТИНЕ'НТ** *м. книж.*— континент (коры җирнең зур бер өлеше, материк).

**КОНТИНЕНТА'ЛЬНЫЙ** — континенталь, континентка хас, материкка хас; *континентальный климат* — континенталь (коры) климат.

**КОНТОКОРРЕ'НТ** *м. банк.*— контокоррент (ике арада расчётлар ясау өчен үзенең даими клиентына учреждение тарафыннан ачыла торган счёт).

**КОНТО'РА** *ж.*— контора.

**КОНТО'РКА I** *ж.*— конторка (аягүрә торып яки биек урындыкка утырып эшләү өчен сөзәк тактады биек өстәл).

**КОНТО'РКА II** *ж. обл.*— пристань.

**КОНТО'РСКИЙ** — контора...-ы; *конторский шкаф* — контора шкафы.

**КОНТО'РЩИК** *м.*, **КОНТО'РЩИЦА** *ж.*— конторщик, конторщица (контора хезмәткәре).

**КО'НТРА I** *ж. разг.*— талаш, ызгыш.

**КО'НТРА II** *книж.*: **про** и **контра** — уңай һәм каршы яклар (моментлар); *взвесить все про и контра* — барлык уңай һәм каршы якларны үлчәп карау.

**КОНТРАБА'НДА** *ж. мн.* нет — контрабанда (1. пошлина салынган яки чыгаруы тыелган товарларны яшерен рәвештә бер илдән икенче илгә чыгару; шулай чыгарылган товарлар; 2. *перен.* нинди дә булса ярамас фикерләрне, карашларны яшерен рәвештә үткәрү; шулай үткәрелгән фикерләр).

**КОНТРАБАНДИ'СТ** *м.*, **КОНТРАБАНДИ'СТКА** *ж.*— контрабандист, контрабандистка (контрабанда белән шөгыльләнүче).

**КОНТРАБА'НДНЫЙ** — контрабанда...-ы, контрабанда юлы белән кертелгән; *контрабандный товар* — контрабанда юлы белән кертелгән товар.

**КОНТРАБА'С** *м. муз.*— контрабас (скрипкага охшаган зур музыка коралы).

**КОНТРАБАСИ'СТ** *м. муз.*—контрабасист, контрабаста уйнаучы.

**КОНТРАБА'СНЫЙ, КОНТРАБА'СОВЫЙ** *муз.*— контрабас...-ы; *контрабасовый смычок* — контрабас смычогы.

**КОНТРА'ГЕНТ** *м. спец.*— контрагент (договор нигезендә үзе өстенә нинди дә булса йөкләмәләр алган кеше яки учреждение).

**КОНТР-АДМИРА'Л** *м. мор.*— контр-адмирал (хәрби флотта адмиралдан ике чинга түбәнрәк звание).

**КОНТРА'КТ** *м.*— контракт, язма договор, килешү.

**КОНТРАКТА'НТ** *м. офиц.*— контрактант (контракт буенча үз өстенә берәр йөкләмә алган кеше).

**КОНТРАКТА'ЦИЯ** *ж.* — контрактация (1. *с.-х.* алдан төзелгән договор буенча продукт әзерләү системасы; 2. алдан төзелгән договор буенча эшчеләр, хезмәткәрләр җыю, вербовать итү).

**КОНТРА'КТНЫЙ** *спец.*— к. контрактовый.

**КОНТРАКТОВА'ТЬ** *несов. офиц.*— 1. контракт төзү, контрактовать итү; контрактация буенча хәзерләү; *контрактовать картофель* — бәрәңге хәзерләүгә контракт төзү; 2. контракт буенча җыю; *контрактовать рабочих* — контракт буенча эшчеләр җыю.

**КОНТРАКТОВА'ТЬСЯ** *несов. офиц.*— 1. контракт буенча йөкләмәләр алу; 2. *страд.* контрактовать ителү, контракт төзелү; контракт буенча хәзерләнү; контракт буенча җыелу.

**КОНТРА'КТОВЫЙ** — контракт...-ы; *контрактовые условия* — контракт шартлары.

**КОНТРА'ЛЬТО** *ср. нескл. муз.*— контральто (1. хатын-кызларда иң калын тавыш; 2. *разг.* шундый тавышлы җырчы хатын-кыз).

**КОНТРА'ЛЬТОВЫЙ** — контральто...-ы; *контральтовая партия* — контральто партиясе.

**КОНТРАМА'РКА** *ж. театр.*— контрамарка (билет урынына бирелә торган талон).

**КОНТРАМА'РОЧНИК** *м.*, **КОНТРАМА'РОЧНИЦА** *ж. разг. фам.*— контрамаркалар белән файдаланучы.

**КОНТРАМА'РОЧНЫЙ** *разг.*— контрамаркалар...-ы; *контрамарочная книжка* — контрамаркалар кенәгәсе.

**КОНТРАПУ'НКТ** *м. мн.* нет, *муз.*— контрапункт (бер үк вакытта яңгырый торган берничә аерым-аерым мелодияне бер бөтенгә кушу сәнгате).

**КОНТРАПУНКТИ'ЧЕСКИЙ** — контрапункт...-ы; контрапункт принципларына нигезләнгән; *контрапунктический стиль* — контрапункт стиле.

**КОНТРАПУ'НКТНЫЙ** — контрапункт...-ы; *контрапунктная теория* — контрапункт теориясе.

**КОНТРАПУНКТОВА'ТЬ** *несов. муз.*— контрапункт кагыйдәләре нигезендә төзү.

**КОНТРА'СТ** *м. книж.*— контраст, кискен каршылык, капма-каршылык.

**КОНТРАСТИ'РОВАТЬ** *несов. книж.*— капма-каршы булу, капма-каршы булып тору; *весёлые песни контрастировали его печальному настроению* — күңелле җырлар аның төшенке настроениесенә капма-каршы иде.

**КОНТРА'СТНОСТЬ** *ж. мн.* нет — контрастлылык, капма-каршылык.

**КОНТРА'СТНЫЙ** — контрастлы, капма-каршы.

**КОНТРАТА'КА** *ж.*— контратака, атакага каршы атака, һөҗүмгә каршы һөҗүм.

**КОНТРАТАКОВА'ТЬ** *сов.* и *несов.*— контратака ясау, каршы һөҗүм ясау.

**КОНТРАФА'КЦИЯ** *ж. книж.*— контрафакция (башка берәүнең әсәрен законсыз рәвештә бастырып авторлык хокукын бозу).

**КОНТРИБУЦИО'ННЫЙ** — контрибуция...-ы; *контрибуционный взнос* — контрибуция взносы.

**КОНТРИБУ'ЦИЯ** *ж.* — 1. *воен. полит.* контрибуция (сугышта җиңелгән дәүләт тарафыннан җиңүче дәүләткә түләнә торган акча); 2. *разг. шутл.* взятка, акча алу.

**КО'НТРИТЬ** *несов. тех.* — хәрәкәтне туктату, тоткарлау (күбесенчә гайканың кире борылып чыгуын туктату турында).

**КОНТРМАНЁВР** *м. воен.* — контрманёвр, манёврга каршы манёвр.

**КОНТРМА'РКА** *ж.* — к. контрамарка.

**КОНТРНАСТУПЛЕ'НИЕ** *ср. воен. спорт.* — һөҗүмгә каршы һөҗүм.

**КОНТРОВЕ'РЗА** *ж.*, **КОНТРОВЕ'РСА** *ж. книж.* — бәхәсле мәсьәлә, фикердә каршылык, гыйльми бәхәс; 2. бәхәс.

**КОНТРОЛЁР** *м.* — контролёр, тикшерүче.

**КОНТРОЛЁРСКИЙ** — контролёр...-ы, контролёрлык...-ы; *контролёрская должность* — контролёрлык вазифасы.

**КОНТРОЛИ'РОВАТЬ** *несов.* — тикшерү, тикшереп тору, күзәтеп тору.

**КОНТРОЛИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд.* — тикшерелү, күзәтелү.

**КОНТРО'ЛЛЕР** *м. тех.* — контроллер (трамвайның, электровозларның һ. б. хәрәкәте белән идарә итә торган аппарат).

**КОНТРО'ЛЬ** — 1. контроль, тикшерү, күзәтеп тору; 2. *собир.* контролёрлар; 3. контроль ясаучы учреждение.

**КОНТРО'ЛЬНЫЙ** — контроль...-ы, тикшерү...-ы; *контрольная комиссия* — контроль комиссиясе.

**КОНТРПА'Р** *м. тех.* — контрпар (пешкәкнең хәрәкәтен тиз генә туктату һәм шуның белән машинаны тормозлау өчен пар машинасының цилиндрына җибәрелә торган пар).

**КОНТРРАЗВЕ'ДКА** *ж. воен.* — контрразведка (чит ил разведкасына, диверсантларына һәм пропагандасына каршы хәрәкәт итә торган учреждение).

**КОНТРРАЗВЕ'ДЧИК** *м.* — контрразведчик, контрразведка работнигы.

**КОНТРРЕВОЛЮЦИОНЕ'Р** *м. полит.* — контрреволюционер, контрреволюциядә катнашучы, контрреволюция тарафдары.

**КОНТРРЕВОЛЮЦИО'ННЫЙ** *полит.* — контрреволюцион; *контрреволюционные банды* — контрреволюцион бандалар.

**КОНТРРЕВОЛЮ'ЦИЯ** *ж. полит.* — контрреволюция (бетүгә йөз тоткан яки бәреп төшерелгән эксплуататор сыйныфларның революциягә кадәр булган тәртипләрне һәм үз өстенлекләрен кайтару өчен революциягә каршы реакцион көрәше).

**КОНТР-УДА'Р** *м.* — контр-удар (дошманның һөҗүменә җавап итеп юнәлдерелгән удар).

**КОНТРФО'РС** *м. архит.* — контрфорс (стенаны терәтү өчен нык терәү).

**КО'НТРЫ** *мн. разг.* — талаш, дошманлык.

**КОНТУ'ЖЕННЫЙ** — контузия алган.

**КОНТУ'ЗИТЬ** *сов.* — контузить итү; *его контузило в голову* — аның башын контузить иткән.

**КОНТУ'ЗИЯ** *ж.* — контузия (якында гына снаряд яки бомба шартлау нәтиҗәсендә организмның берәр кисәгенең тыштан яраланмыйча гына имгәнүе, зәгыйфьләнүе).

**КО'НТУР** *м.* — контур (предметның тышкы кыяфәте, сызыклар белән генә ясалган рәсеме).

**КО'НТУРНЫЙ** — контур...; *контурный рисунок* — контур рәсем.

**КОНУРА'** *ж.* — 1. эт оясы; 2. *перен. разг.* кечкенә, тар бүлмә.

**КО'НУС** *м.* — конус (1. *мат.* туры почмаклы өчпочмакны катетларының берсе тирәсендә әйләндерүдән килеп чыга торган геометрик җисем; формасы белән геометрик конуска охшаган һәрбер физик җисем; 2. *тех.* автомобильдә хәрәкәтне мотордан арткы көпчәкләргә тапшыра торган механизм).

**КОНУСОВИ'ДНЫЙ, КОНУСООБРА'ЗНЫЙ** — конуссыман.

**КОНФЕДЕРА'ЦИЯ** *ж. право* — 1. конфедерация, союз, берләшмә; *конфедерация труда* — хезмәт конфедерациясе (Франциядә профсоюзлар берләшмәсе); 2. конфедерация (а. иске Польшада үзләренең сыйнфый хокукларын саклау һәм Польшаның бәйсезлеге өчен көрәшкән алпавытларның кораллы союзы; б. бәйсезлекләрен саклаган, ләкин бер яки берничә гомуми органнары булган дәүләтләр союзы).

**КОНФЕ'КТ** *м.*, **КОНФЕ'КТА** *ж. устар.* — к. конфета.

**КОНФЕКЦИО'Н** *м.* — конфекцион (әзер киемнәр магазины).

**КОНФЕКЦИО'ННЫЙ** — конфекцион, әзер киемнәр эшләп чыгара торган.

**КОНФЕРА'НС** *м. театр.* — конферанс, конферансьеның белдерүе.

**КОНФЕРАНСЬЕ'** *м. нескл. театр.* — конферансье (тамашаның программасын публикага белдереп һәм аңлатып торучы).

**КОНФЕРЕ'НЦ-ЗАЛ** *м. офиц.* — конференц-зал (тантаналы утырышлар, киңәшмәләр залы).

**КОНФЕРЕ'НЦИЯ** *ж.* — конференция (аерым мәсьәләләрне тикшерү өчен дәүләтләр, оешмалар тарафыннан җибәрелгән делегатлар җыелышы, киңәшмәсе).

**КОНФЕ'ТА** *ж.* — конфет, кәнфит.

**КОНФЕ'ТНЫЙ** — 1. конфет ...-ы; *конфетная бумажка* — конфет кәгазе; 2. *перен. разг. фам. пренебр.* төче, төче телләнеп ...-ган, ялагай; *конфетный молодой человек* — ялагай яшь егет; *конфетные стишки* — төче телләнеп язылган шигырьләр.

**КОНФЕТТИ'** *ср. нескл.* — конфетти (балларда, маскарадларда бер-береңң өстенә сибәр өчен ваклап, түгәрәкләп киселгән төрле төстәге кәгазь кисәкләре).

**КОНФЕ'ТЧИК** *м.*, **КОНФЕ'ТЧИЦА** *ж.* — конфетчы, конфет фабрикасы эшчесе.

**КОНФИГУРА'ЦИЯ** *ж. книж.* — 1. конфигурация, кыяфәт, күренеш, сурәт; 2. конфигурация (нинди дә булса әйберләрнең үзара тәртипле рәвештә куелышы, урнашуы; *конфигурация звёзд на небе* — күктәге йолдызларның үзара тәртипле рәвештә урнашуы).

**КОНФИДЕНЦИА'ЛЬНО** *нареч.* — конфиденциаль рәвештә, яшерен рәвештә, сер итеп.

**КОНФИДЕНЦИА'ЛЬНЫЙ** — конфиденциаль, яшерен, сер итеп саклана торган.

**КОНФИРМА'ЦИЯ** *ж. книж.* — конфирмация (1. *устар.* карарның югары власть тарафыннан раслануы; 2. *церк.* протестантларда чукындыру йоласы).

**КОНФИСКА'ЦИЯ** *ж. офиц.* — конфискация (дәүләт властеның карары буенча берәүнең акчасын яки мал-мөлкәтен тартып алу).

**КОНФИСКОВА'ТЬ** *сов.* и *несов. офиц.* — конфискацияләү, конфисковать итү, мал-мөлкәтен тартып алу, конфискация ясау.

**КОНФИСКОВА'ТЬСЯ** *сов.* и *несов. страд. офиц.* — конфискацияләнү, конфисковать ителү, мал-мөлкәте тартып алыну, конфискация ясалу.

**КОНФЛИ'КТ** *м. книж.* — 1. конфликт, низаг, бәрелеш; 2. конфликт (халыкара мөнәсәбәтләрнең кискенләшүе).

**КОНФЛИ'КТНЫЙ** *книж. офиц.* — 1. конфликтлы, низаглы; *конфликтный вопрос* — конфликтлы мәсьәлә; 2. конфликт ... -ы, конфликтларны хәл итә торган; *конфликтная комиссия* — конфликт комиссиясе, конфликтларны хәл итә торган комиссия.

**КОНФЛИКТОВА'ТЬ** *несов. простореч.* — низаглашу.

**КОНФО'РКА** *ж.* — конфорка (1. самовар конфоркасы; 2. кухня плитасының тишеген каплый торган түгәрәк япкыч).

**КОНФУ'З** *м. разг.* — конфуз, уңайсыз хәл, аптыраш; *вот какой конфуз получился* — менә нинди конфуз килеп чыкты.

**КОНФУ'ЗИТЬ** *несов. разг.* — оятка калдыру, оятлы итү, көлкегә калдыру, йөзен кызарту, уңайсыз хәлдә калдыру, мәсхәрә итү.

**КОНФУ'ЗИТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. *без доп.* оятка калу, оятлы булу, көлкегә калу; аптырашта калу; 2. *кого-чего* тартыну, оялу, уңайсызлану; *он вас конфузится* — ул сездән тартына, ул сездән ояла.

**КОНФУ'ЗЛИВОСТЬ** *ж. мн.* нет — оялчанлык, тартынучанлык.

**КОНФУ'ЗЛИВЫЙ** — оялчан, тартынучан.

**КОНФУ'ЗНЫЙ** *простореч.* — оятка калырлык, оятка калдырырлык.

**КОНЦЕВО'Й** *спец.* — очтагы, ахырдагы, актыккы, соңгы.

**КОНЦЕ'НТР** *м. педаг.* — концентр (фәннең, дәрес предметының төп эчтәлеге бер үк булган, ләкин кайсы баскычта үтелүенә карап, күләме һәм катлаулылыгы белән берберенннән аерыла торган бүлекләре).

**КОНЦЕНТРА'Т** *м.* — концентрат (1. *горн.* баетылган руда; 2. *с.-х.* көчле азык, туклыклы азык; 3. коры, прессовать ителгән әзер азык продукты).

**КОНЦЕНТРА'ЦИЯ** *ж. книж.* — 1. *к.* концентрировать и концентрироваться; 2. *хим.* концентрация (куелык дәрәҗәсе).

**КОНЦЕНТРИ'РОВАТЬ** *несов. книж.* — 1. җыю, туплау; *концентрировать войска* — гаскәрләрне җыю (туплау); 2. юнәлтү, юнәлдерү, туплау; *концентрировать внимание* — игътибарны юнәлдерү; 3. (*о жидкости*) куеландыру, куерту; 4. (*о руде*) баету.

**КОНЦЕНТРИ'РОВАТЬСЯ** *несов. книж.* — 1. җыелу, тuплану; 2. юнәлү, туплану; 3. *спец.* куеру; 4. *страд.* юнәлдерелү; куертылу.

**КОНЦЕНТРИ'ЧЕСКИЙ, КОНЦЕНТРИ'ЧНЫЙ** — 1. үзәктәш; *концентрические круги* — үзәктәш түгәрәкләр; 2. концентрик, концентрларга бүленгән; *концентрическая система преподавания* — укытуда концентрик система, концентрларга бүлеп укыту системасы.

**КОНЦЕНТРИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — үзәктәшлек; концентриклык, үзәкләштерелгәнлек.

**КОНЦЕ'ПТ** *м.* — гомуми төшенчә, гомуми рәвештә күз алдына китерү.

**КОНЦЕ'ПЦИЯ** *ж. книж.* — концепция (төрле мәсьәләләргә, чынбарлыкта булып тора торган хәл һәм күренешләргә караш лар системасы).

**КОНЦЕ'РН** *м.* — концерн (капиталистик монополияләрнең бер төре).

**КОНЦЕ'РТ** *м.* — 1. концерт (а. музыкаль яки вокаль әсәрне халык алдында башкару; б. оркестрга кушылып бирәр инструментта, мәсәлән, скрипкада, башкару өчен язылган музыкаль әсәр); 2. *перен.* берничә дәүләтнең бергәләп чыгышы. ◇ Кошачий концерт *перен. разг. шутл.* — мәче туе, мәче концерты (колак тондыргыч шау-шу, кычкырулар).

**КОНЦЕРТА'НТ** *м.*, **КОНЦЕРТА'НТКА** *ж.* — концерт бирүче артист(ка).

**КОНЦЕРТИ'НО** *м.* и *ср. нескл. муз.* — алты кырлы гармонь.

**КОНЦЕРТИ'РОВАТЬ** *несов. книж.* — концертлар бирү.

**КОНЦЕРТМЕ'ЙСТЕР** *м. муз.* — концертмейстер (1. оркестрда беренче скрипач; 2. опера театрында җырчыларга үз партияләрен өйрәнүдә ярдәм итүче музыкант-аккомпаниатор).

**КОНЦЕ'РТНЫЙ** *муз.* — концерт ...-ы; *концертная программа* — концерт программасы; *концертный зал* — концерт залы.

**КОНЦЕССИОНЕ'Р** *м.* — концессионер, концессия хуҗасы, концессия алган кеше.

**КОНЦЕССИОНЕ'РСКИЙ** — концессионер... -ы; *концессионерский капитал* — концессионер капиталы.

**КОНЦЕССИО'ННЫЙ** — 1. концессия ...-ы; *концессионный договор* — концессия договоры; 2. концессиягә бирелгән; *концессионная фабрика* — концессиягә бирелгән фабрика.

**КОНЦЕ'ССИЯ** *ж.* — концессия (1. берәр дәүләт тарафыннан аерым капиталистка промышленность предприятиесе төзү өчен билгеле бер шартларда бирелгән рөхсәт; 2. шундый рөхсәт нигезендә төзелгән һәм эшли торган предприятие).

**КОНЦЛА'ГЕРЬ** *м. офиц.* — концентрацион лагерь (хәрби тоткыннарны яки социаль куркынычлы кешеләрне ябып, камап тоту урыны).

**КОНЦО'ВКА** *ж.*— 1. *тип.* концовка (китап яки аның аерым бүлегенең ахырында куела торган рәсем-бизәк); 2. *перен.* әсәрнең соңгы, азакқы өлеше.

**КОНЧА'ТЬ** *несов.*— 1. бетерү, тәгәлләү, тәмамлау, очлау, тәмам итү; 2. *(прекратить)* өзү, туктату; 3. *простореч.* юк итү, үтерү.

**КОНЧА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. бетү, тәгәлләнү, тәмамлану, очлану, тәмам булу; 2. *простореч.* үлү.

**КО'НЧЕНО** — бетте! җитте!

**КО'НЧЕНЫЙ** *разг.*— хәл ителгән, беткән. ◇ **Человек конченый** *разг.*— эштән чыккан кеше, беткән кеше.

**КО'НЧИК** *м. разг.*— 1. оч, баш; *кончик верёвки* — бауның очы; 2. иң ахыры, иң азагы; *застал лекцию на кончике* — лекциянең иң ахырына гына өлгердем. ◇ **Сахар-то у нас на кончике** — шикәребез бетеп килә, беттегә исәп.

**КОНЧИ'НА** *ж. мн.* нет, *книж. ритор.*— үлем.

**КО'НЧИТЬ** *сов.*— к. кончать. ◇ **Кончить дурно, плохо, скверно** *разг.*— 1. түбәнлеккә төшү, кызганыч хәлгә барып җитү; 2. үзенне үзең үтерү.

**КО'НЧИТЬСЯ** *сов.*— к. кончаться.

**КОНЪЕКТУ'РА** *ж.*— 1. *филос.* конъектура, гөман, фараз (шулай булса кирәк дип уйлау); 2. *филол.* элекке хәленә кайтару (бозылган текстны искә төшереп элекке хәленә кайтару).

**КОНЪЮНКТИ'ВА** *ж. анат.* — конъюнктива (күз кабакларын күз белән тоташтыра торган лайлалы яры).

**КОНЪЮНКТИВИ'Т** *м. мед.*— конъюнктиваның ялкынсынуы.

**КОНЪЮНКТУ'РА** *ж. книж.*— конъюнктура (1. берәр эшнең нәтиҗәсенә тәэсир итә торган барлык шартлар; 2. *экон.* товар хуҗалыгының хәлен билгели торган барлык шартлар).

**КОНЬ** *м.*— ат, елкы. ◇ **Не в коня корм** *разг.*— ишәк түшәк кадерен белмәс.

**КОНЬКИ'** *мн.* — коньки, тимераяк.

**КОНЬКОБЕ'ЖЕЦ** *м. спорт.* — тимераякта шуучы, коньки шуучы.

**КОНЬКОБЕ'ЖИЦА** *ж. спорт.*— к. конькобежец.

**КОНЬКОБЕ'ЖНЫЙ** — тимераякта шуу ...-ы; коньки шуу ...-ы; *конькобежные состязания* — тимераякта шуу ярышлары, коньки шуу ярышлары.

**КОНЬЯ'К** *м.*— коньяк (виноград аракысы).

**КОНЬЯ'ЧНЫЙ** — коньяк ...-ы; *коньячный запах* — коньяк исе.

**КО'НЮХ** *м.*—конюх, ат караучы.

**КОНЮ'ШНЯ** *ж.*— 1. конюшня, ат абзары; 2. *перен. простореч. пренебр.*— үтә пычрак бүлмә (бина).

**КОНЯ'ГА** *ж. обл.*— аткай, бахбай.

**КООПЕРАТИ'В** *м.*— кооператив (1. кооперация оешмасы; 2. кооператив магазины).

**КООПЕРАТИ'ВНЫЙ** — кооперация ...-ы; *кооперативные организации* — кооперация оешмалары.

**КООПЕРА'ТОР** *м.*— кооператор (кооперация өлкәсендә эшләүче, кооперативта эшләүче).

**КООПЕРА'ЦИЯ** *ж.* — кооперация (1. бер үк хезмәт процессында яки хезмәтнең үзара бәйләнгән төрле процессларында күп кешеләрнең бергәләшеп эш күрүе, эш башкаруы; 2. производство һәм сәүдә өлкәсендә массовый коллектив берләшмә; *промысловая кооперация* — һөнәрчеләр кооперациясе).

**КООПЕРИ'РОВАНИЕ** *ср. мн.* нет — к. кооперировать һәм кооперироваться.

**КООПЕРИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.*— 1. кооперацияләштерү (бергәләп эшләү нигезендә берләштерү); 2. кооперациягә членлыкка тарту.

**КООПЕРИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов.* — 1. кооперацияләшү(бергәләп эшләү нигезендә берләшү); 2. *страд.* кооперацияләштерелү (бергәләп эшләү нигезендә берләштерелү).

**КООПТА'ЦИЯ** *ж.*— кооптация (сайлану юлы белән эшли торган оешмаларга сайлаучыларга мөрәҗәгать итмичә яңа членнар кабул итү, тарту).

**КООПТИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.*— кооптировать итү (читтән яңа член тарту).

**КООРДИНА'ТЫ** *мн. мат.*— координатлар (нокталның яссылык өстендәге яки пространстводагы торышын билгели торган зурлыклар).

**КООРДИНА'ТНЫЙ** *мат.*—координат...-ы; *координатные оси* — координат күчәрләре.

**КООРДИНА'ЦИЯ** *ж.*— координация, үзара килешкәнлек, ярашканлык.

**КООРДИНИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. книж.* — координацияләү, яраклаштыру, яраштыру, килештерү.

**КООРДИНИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. книж.* — 1. яраклашу, ярашу, килешү; 2. *страд.* координацияләнү, яраклаштырылу, яраштырылу, килештерелү.

**КОПА'Л** *м. спец.*— копал (лак ясауга китә торган сумала).

**КОПА'ЛОВЫЙ** — копалдан ясалган; *копаловый лак* — копалдан ясалган лак.

**КОПА'ТЬ** *несов.*—1. казу; 2. казып йомшарту, күпертү; 3. *(картофель)* алу, казу.

**КОПА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. *(рыться)* казыну; 2. *(искать, перебирая)* актарыну; 3. *перен.* чокчыну; 4. *(долго возиться)* казыну, кайнашу, маташу, озакка сузу; 5. *страд.* казылу, казып йомшартылу.

**КОПЕ'ЕЧКА** *ж. разг.*— к. копейка. ◇ **В копеечку стать (вскочить, обойтись, влететь)** *разг. фам.*— бик кыйбатка төшү.

**КОПЕ'ЕЧНИК** *м. простореч. пренебр.*— саран, вакчыл.

**КОПЕ'ЕЧНЫЙ** — 1. *(стоящий копейку)* бер тиенлек, бер тиен тора торган; 2. вактәяк; *копеечные расходы* — вак-төяк расходлар; 3. *перен. разг.* бик вакчыл, бик саран; *копеечная душа* — бик саран, бик вакчыл кеше.

[копеечный] — ... тиенлек; *трёхкопеечная монета* — өч тиенлек акча.

**КОПЕ'ЙКА** *ж.*— бер тиен, бер тиенлек

акча. ◇ **В копейку** — к. в копеечку. **Копейка в копейку** *разг.* — тиененә кадәр.

**КОПЁНКА** *ж. обл.* — кечкенә чүмәлә.

**КОПЁР** *м.* — копёр (субай сугу машинасы).

**КО'ПИ** *мн.* (*ед.* копь *ж.*) — копи, шахта.

**КОПИИ'СТ** *м. офиц. устар.* — копияләр алучы.

**КОПИ'ЛКА** *ж.* — копилка (акча җыю өчен кечкенә тартма).

**КОПИ'РКА** *ж. разг.* — копирка, копировка, копировка кәгазе.

**КОПИРОВА'ЛЬНЫЙ** — копировка ...-ы; *копировальные чернила* — копировка карасы; *копировальная бумага* — копировка кәгазе.

**КОПИРОВА'ТЬ** *несов.* — **1.** копиясен алу, күчермәсен алу; **2.** ... булып кылану, ...-ча кылану; *он очень смешно копировал своих учителей* — ул бик көлке итеп үзенең укытучылары булып кылана иде.

**КОПИРОВА'ТЬСЯ** *несов.* — копиясе алыну, күчермәсе алыну.

**КОПИРО'ВКА** *ж. мн.* нет, *разг.* — к. копировать 1.

**КОПИРО'ВОЧНЫЙ** — к. копировальный.

**КОПИРО'ВЩИК** *м. спец.* — копиясен алучы, күчермәсен алучы.

**КОПИ'ТЬ** *несов.* — 1. саклыкка җыю, запас туплау; **2.** *перен.* җыю, җыеп саклау, яшереп саклау; *копить злобу* — ачу саклау.

**КОПИ'ТЬСЯ** *несов.* — **1.** җыелу, җыела бару, җыела килү, җыела тору; **2.** *страд.* саклыкка җыелу, запас туплану.

**КО'ПИЯ** *ж.* — 1. копия, күчермә; **2.** нәкъ үзе, копиясе; *мальчик совершенная копия отца* — малай нәкъ этисе (малай койган да куйган — нәкъ этисе; этисенә бик охшаган).

**КОПНА'** *ж.* — чүмәлә. ◇ **Копна волос** *разг.* — куе тузгак чәч.

**КОПНИ'ТЬ** *несов.* — чүмәлә кую.

**КОПНУ'ТЬ** *однокр.* — 1. казып карау; **2.** *перен.* кагылып карау, тиеп карау; *тут только копни — сразу недостатки обнаружатся* — биредә кагылып кына кара — шунда ук җитешсезлекләр ачылыр.

**КО'ПОТКИЙ** *обл.* — к. копотливый.

**КОПОТЛИ'ВОСТЬ** *ж. мн.* нет, *разг.* — сүлпәнлек, әкренлек.

**КОПОТЛИ'ВЫЙ** *разг.* — **1.** сүлпән, әкрен кыймылдаучан, мыштым; **2.** озак вакыт сорый торган, әкрен эшләнә торган.

**КО'ПОТНЫЙ** *обл.* — к. копотливый.

**КОПОТНЯ'** *ж. мн.* нет, *простореч.* — әкрен кыймылдау, озак маташу.

**КОПОТУ'Н** *м.*, **КОПОТУ'НЬЯ** *ж. простореч.* — әкрен кыймылдаучы, мыштым, сүлпән (кеше).

**КО'ПОТЬ** *ж. мн.* нет — корым, сөрем.

**КОПОШИ'ТЬ** *несов. простореч.* — кыймылдату, мыж китерү.

**КОПОШИ'ТЬСЯ** *несов.* — **1.** кыймылдау, мыж килү, кайнап тору; *муравьи копошатся возле муравейника* — кырмыскалар оялары янында мыж киләләр; **2.** *разг.* (*возиться с чем-н.*) казыну, кайнашу, маташу; **3.** *перен. разг.* буталу, чуалу; *мысли копошатся в голове* — башымда фикерләрем бутала (чуала).

**КОПРО'М** *нареч.* — тырпаеп; *нечёсаные волосы торчали копром* — таралмаган чәчләре тырпаеп торалар иде.

**КОПТЕ'ТЬ** I. *несов. просторечи.* — корымлану, корым белән каплану, ыслану, сөремләнү.

**КОПТЕ'ТЬ** II *несов. разг. фам.* — к. корпеть.

**КОПТИ'ЛКА** *ж. разг. пренебр.* — сукыр лампа.

**КОПТИ'ЛЬНЫЙ** *спец.* — ыслау...-ы; *коптильный завод* — ыслау заводы.

**КОПТИ'ЛЬНЯ** *ж. спец.* — ыслау урыны.

**КОПТИ'ЛЬЩИК** *м.спец.* — ыслаучы (эшче).

**КОПТИ'ТЬ** *несов.* — **1.** төтәү, сөрем чыгару; *лампа коптит* — лампа төти; **2.** (*о мясе, рыбе*) ыслау; **3.** корымлау; *коптить стекло для наблюдения солнечного затмения* — кояш тотылуын күзәтү өчен пыяланы корымлау.

**КОПТИ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — ыслану.

**КОПУЛИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. спец.* — бөреле ботак ялгау (агачка).

**КОПУЛИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. страд.* — бөреле ботак ялгану.

**КОПУ'Н** *м.*, **КОПУ'НЬЯ** *ж.*, **КОПУ'ША** *м.* и *ж. простореч. фам.* — сүлпән кеше, әкрен кыймылдаучы кеше.

**КОПЧЁНКА** *ж. обл.* — ысланган балык, ысланган ит, ыслап какланган ит, балык һ. б.

**КОПЧЁНОСТЬ** *ед.* нет, *спец.* — ысланган азыклар, ыслап какланган азыклар.

**КОПЧЁНЫЙ** — ысланган, ыслап хәзерләнгән, ыслап какланган, ыслап һәм каклап хәзерләнгән.

**КО'ПЧИК** I *м. анат.* — койрык сөяге, койрык умырткасы.

**КО'ПЧИК** II *м. зоол.* — к. кобчик.

**КОПЧУ'ШКА** *ж. разг.* — ыслап какланган вак балык.

**КОПЫ'Л** *м. обл.* — чана теше, чана тырнагы.

**КОПЫ'ТНЫЕ** *зоол.* — тояклылар.

**КОПЫ'ТНЫЙ** — тояк ...-ы; *копытная мазь* — тояк мае.

**КОПЫ'ТО** *ср.* — тояк.

**КОПЫ'ТЦЕ** *ср.* — кечкенә тояк.

**КОПЬ** *ж.* — к. копи.

**КОПЬЁ** I *ср.* — сөңге. ◇ **Копья ломать** *книж.* — бәхәсләшү, әреплләшү.

**КОПЬЁ** II *ср. устар.* — акчаның күн ягы. ◇ **Ни копья (нет)** *простореч.* — сукыр бер тиен дә юк.

**КОПЬЕВИ'ДНЫЙ, КОПЬЕОБРА'ЗНЫЙ** *книж.* — сөңгесыман.

**КОПЬЕНО'СЕЦ** *м. истор.* — сөңгеле сугышчы.

**КОРА'** *ж. мн.* нет — **1.** кабык, кайры; **2.** (*наружный слой мозга*) ми сүрүе, ми кабыгы.

**КОРАБЕ'ЛЬНЫЙ** — корабль ...-ы, кораблъләр ...-ы; *корабельная снасть* — корабль кирәк-яраклары.

**КОРАБЛЕВОЖДЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *мор.*— корабль йөртү (кагыйдәләрен өйрәтә торган фән).

**КОРАБЛЕКРУШЕ'НИЕ** *ср.*— корабль һәлакәте.

**КОРАБЛЕСТРОЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *спец.*— карабльләр төзү; корабльләр төзү турындагы фән.

**КОРАБЛЕСТРОИ'ТЕЛЬ** *м.*— корабльләр төзүче.

**КОРАБЛЕСТРОИ'ТЕЛЬНЫЙ** — корабльләр төзү ...-ы; *кораблестроительное искусство* — корабльләр төзү сәнгате.

**КРА'ТКИЙ** — 1. кыска, аз гына...; *на краткий срок* — кыска вакытка, аз гына вакытка; 2. кыскартылган, кыскача; *краткий курс химии* — химиянең кыскача курсы; 3. *лингв.* кыска; *краткие гласные* — кыска сузыклар. ◇ **Краткие встречи** — аз гына вакытка очрашулар. **В кратких словах** — кыскача әйткәндә. **И краткое** — й хәрефе.

**КРА'ТКО** *нареч.* — кыска итеп, кыскача, кыскача гына.

**КРАТКОВРЕ'МЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— вакыт кыскалык, вакыт азлык.

**КРАТКОВРЕ'МЕННЫЙ** — кыска вакытлы.

**КРАТКОСРО'ЧНЫЙ** *офиц. книж.*— кыска сроклы, кыска вакытлы.

**КРА'ТКОСТЬ** *ж. мн.* нет — кыскалык.

**КРА'ТНОЕ** *в знач. сущ. мат.*— кабатлы сан.

**КРА'ТНОСТЬ** *ж. мн.* нет — кабатлылык.

**КРАТ'НЫЙ** *мат.*— кабатлы.

**КРАТЧА'ЙШИЙ** *книж.* — иң кыска; иң якын.

**КРАХ** *м.*— 1. бөлү; 2. *перен.* тулы уңышсызлык, һәлакәт, бетү; *крах капитализма* — капитализмның һәлакәте.

**КРАХМА'Л** *м. мн.* нет — крахмал.

**КРАХМА'ЛИСТЫЙ** *спец.*— күп крахмаллы, крахмалга бай.

**КРАХМА'ЛИТЬ** *несов.* — крахмаллау, крахмаллы суга ману.

**КРАХМА'ЛЬНЫЙ** — 1. крахмал...-ы; *крахмальный завод* — крахмал заводы; 2. крахмаллы, крахмалланган; *крахмальный воротник* — крахмалланган яка.

**КРА'ЧКА** *ж. зоол.*— диңгез акчарлагы.

**КРА'ШЕ** *простореч.* и *устар.*— матуррак, чибәррәк, яхшырак.

**КРАШЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *тех.*— к. красить.

**КРАШЕНИ'НА** *ж. мн.* нет, *обл.* — буяуга манылган киндер.

**КРА'ШЕНЫЙ** — 1. буялган, буяуга манылган; 2. *разг. презрит.* бизәнгән, кершән ягынган.

**КРАЮ'ХА** *ж. простореч.*— кибән башы (бөтен икмәкнең беренче телеме).

**КРАЮ'ШКА** *ж. простореч.*— к. краюха.

**КРЕАТУ'РА** *ж. книж. пренебр.*— креатура (берәр сүзе үтүчән кешенең яки сүз-

ләре үтүчән иҗтимагый даирәләрнең ярдәме белән зур урынга күелган кеше); *этот министр был креатурой банкиров* — ул министр банкирларның креатурасы иде.

**КРЕВЕ'ТКА** *ж.* — диңгез кысласы.

**КРЕ'ДИТ** *м. бухг.* — кре́дит (бухгалтерия кенәгәсенең чыгымнар языла торган ягы).

**КРЕДИ'Т** *м.* — 1. кредит, бурычка бирү, бурыч; 2. *перен. книж.* ышаныч, абруй.

**КРЕДИТИ'В** *м. банк.* и *дипл.* — к. аккредитив.

**КРЕДИ'ТКА** *ж.* — кәгазь акча.

**КРЕДИ'ТНЫЙ** — кредит...-ы; *кредитные операции* — кредит операцияләре.

**КРЕДИТОВА'ТЬ** *сов.* и *несов. фин.* — бурычка бирү, бурыч итеп бирү, кредитка бирү.

**КРЕДИТОВА'ТЬСЯ** *сов.* и *несов. фин.* — 1. бурычка алу, кредит алу; 2. *страд.* бурычка бирелү, бурыч итеп бирелү.

**КРЕ'ДИТОВЫЙ** *бухг.* — кре́дит...-ы; *кредитовая страница* — кредит бите.

**КРЕДИТО'Р** *м.* — кредитор, бурычка бирүче.

**КРЕДИТО'РСКИЙ** — кредитор...-ы; *кредиторский счёт* — кредитор счёты.

**КРЕДИТОСПОСО'БНОСТЬ** *ж. мн.* нет — бурыч түләүгә сәләтлелек.

**КРЕДИТОСПОСО'БНЫЙ** — бурыч түләүгә сәләтле.

**КРЕДИ'ТЫ** *мн.* — берәр расходка бирелгән сумма, акча (берәр расход өчен билгеләнгән акча).

**КРЕ'ДО** *ср. нескл. книж.* — кредо, берәүнең фикерләре, төп ышанычы, шәхси карашлары; *изложить своё кредо* — үзеңнең фикерләреңне әйтеп бирү.

**КРЕЗ** *м. книж.* — крез (чиксез байлыклар иясе).

**КРЕ'ЙСЕР** *м. воен. мор.* — крейсер (тиз йөрешле зур сугыш корабле).

**КРЕ'ЙСЕРСКИЙ** — крейсер...-ы; *крейсерский ход* — крейсер йөреше. ◇ **Крейсерская скорость** *авиац.* — очышның нормаль тизлеге.

**КРЕЙСИРОВА'ТЬ** *несов. мор.* — йөрү, йөреп тору, рейслар ясау; *пароходы крейсируют между Одессой и Севастополем* — пароходлар Одесса белән Севастополь арасында йөреп торалар.

**КРЕ'КИНГ** *м. тех.* — крекинг, нефть куу заводы.

**КРЕ'КИНГ-ПРОЦЕ'СС** *м. тех.* — нефть куу (термик эшкәртү юлы белән нефтьтән бензин һ. б. алу).

**КРЕКИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. тех.* — нефтьне эшкәртү (нефтьтән бензин һ. б. аерып алу).

**КРЕМ** *м.* — крем (1. татлы ашамлык; 2. косметик май; 3. аяк киемнәре чистарту мае).

**КРЕМАТО'РИЙ** *м.* — крематорий (мәет яндыру бинасы).

**КРЕМАЦИО'ННЫЙ** *спец.* — мәет яндыру...-ы; *кремационная печь* — мәет яндыру миче.

**КРЕМА'ЦИЯ** *ж.* — мәетләрне яндыру.

**КРЕМЕ'НЬ** *м.* — 1. чакма ташы; 2. *перен. простореч.* каты кеше, саран кеше.

**КРЕМЛЁВСКИЙ** — кремль...-ы; *кремлёвские ворота* — кремль капкасы.

**КРЕМЛЬ** *м.* — кремль (борынгы шәһәрләрдә крепость, ныгытма).

**КРЕМНЁВКА** *ж. истор.* — борынгы мылтык (чакма белән атыла торган).

**КРЕМНЁВЫЙ** — 1. чакмалы, чакма ташлы (корал); 2. *перен. устар.* нык, чыдам, нык характерлы.

**КРЕМНЕЗЁМ** *м. мн.* нет, *хим. мин.* — кремнезём (кремнийның кислород белән кушылмасы).

**КРЕМНЕЗЁМИСТЫЙ** *хим. мин.* — кремнезёмлы; *кремнезёмистая почва* — кремнезёмлы туфрак.

**КРЕ'МНИЕВЫЙ** *хим.* — силикат...-ы; *кремниевая кислота* — силикат кислотасы.

**КРЕ'МНИЙ** *м. хим.* — кремний (күпчелек тау токымнарының составына керә торган химик элемент).

**КРЕМНИ'СТЫЙ** — 1. ташлы; 2. *мин.* кремнезёмлы, кремнезёмнан тора торган.

**КРЕ'МОВЫЙ** — 1. аксыл сары (төсгәге); 2. кремлы; *кремовое пирожное* — кремлы пирожный.

**КРЕН** *м. спец.* — 1. кырынаю, авышу, янтаю (судно, очкыч аппарат турында); 2. *перен. газет.* политик тайпылыш.

**КРЕ'НДЕЛЬ** *м.* — крендель. ◇ **Свернуться кренделем** *разг.* — бөгәрләнеп яту. **Кренделя писать** *разг.* — алпан-тилпән бару, ава-түнә бару. **Ни за какие крендели** *простореч.* — һич тә, һичбер очракта да.

**КРЕ'НДЕЛЬНЫЙ** — крендель...-ы; *крендельное тесто* — крендель камыры.

**КРЕ'НДЕЛЬЩИК** *м. спец.* — крендельче, крендель пешерүче яки сатучы.

**КРЕНИ'ТЬ** *несов. мор.* — 1. кырынайту, кыйшайту, янтайту (судноны); *сильный ветер кренит лодку* — көчле җил көймәне кырынайта; 2. *безл.* кырынаю, янтаю; *пароход сильно кренило* — пароход бик нык кырыная иде.

**КРЕНИ'ТЬСЯ** *несов. мор.* — кырынаю, кыйшаю, янтаю (судно).

**КРЕОЗО'Т** *м. мн.* нет, *хим.* — креозот (дегетсыман матдә).

**КРЕО'Л** *м.* — креол (1. Көньяк Америкага Европадан күчеп барган колонизаторларның шунда туган балалары; 2. гомумән — берәр илдә чит расадан булган ата-аналардан туган кеше).

**КРЕП** *м.* — креп (үтә күренмәле кытыршы ефәк яки мамык тукыма, гадәттә кара төстә була).

**КРЕПДЕШИ'Н** *м.* — крепдешин (тыгыз һәм юка ефәк тукыма).

**КРЕПДЕШИ'НОВЫЙ** — крепдешин..., крепдешиннан тегелгән; *крепдешиновое платье* — крепдешин күлмәк.

**КРЕПЁЖНЫЙ** *горн.* — (шахталарны) ныгыту...-ы; *крепёжный лес* — шахталарны ныгыту агачлары.

**КРЕПИ'ЛЬЩИК** *м. спец.* — крепильщик, ныгытучы (шахтада).

**КРЕПИ'ТЕЛЬНЫЙ** — 1. *горн.* ныгыту...-ы;

*крепительные работы* — ныгыту эшләре; 2. *мед.* ашказанын ныгыту...-ы; эч китүне туктату...-ы; *крепительные лекарства* — ашказанын ныгыту дарулары.

**КРЕПИ'ТЬ** *несов.* — 1. ныгыту; *крепить набережную* — яр буйларын ныгыту; 2. ныклап бәйләп кую; *крепить канат* — арканны ныклап бәйләп кую. 3. *мед.* эчне катыру. ◇ **Крепить паруса** *мор.* — җилкәннәрне җыю, төшерү.

**КРЕПИ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. тыелып тору, үзен-үзе тыеп тору; 2. *ритор.* чыдамлык күрсәтү; 3. *страд.* ныгытылу, ныгайтылу.

**КРЕ'ПКИЙ** — 1. (*прочный*) каты, нык; 2. (*выносливый, здоровый*) таза, чыдам, түземле; 3. көчле, нык; *крепкий ветер* — көчле җил; *крепкий организм* — нык организм; 4. (*насыщенный, сгущённый*) каты, куе, көчле; *крепкий чай* — каты (куе) чәй; *крепкое вино* — көчле аракы; *крепкий табак* — каты тәмәке; 4. ышанычлы; *крепкое слово* — ышанычлы сүз; 5. (*неизменный, глубокий*) ныклы, тирән; *крепкая дума* — тирән уй. ◇ **Крепкий сон** — уянмас йокы, каты йокы. **Крепкие напитки** — спиртлы эчемлекләр. **Крепкое словцо** *разг.* — сүгенү сүзе. **Крепкий на ухо** — колакка каты (начар ишетә).

**КРЕ'ПКО** *нареч.* — каты, нык; *парус привязан крепко* — җилкән нык бәйләнгән; *крепко заболел* — бик каты авырып китте. ◇ **Крепко выражаться** — сүгенү. **Крепко-накрепко** — бик нык итеп; кырт кисеп.

**КРЕПКОГОЛО'ВЫЙ, КРЕПКОЛО'БЫЙ** *разг. ирон.* — аңгыра, аңсыз, мингерәү.

**КРЕПКОНО'ГИЙ** — нык йөрешле, таза аяклы.

**КРЕПЛЕ'НИЕ** *ср.* — 1. к. крепить; 2. ныгытма (шахталарда ишелүдән саклану өчен эшләнгән корылмалар); 3. беркеткеч; *у лыжи лопнуло крепление* — чаңгының беркеткече өзелгән.

**КРЕ'ПНУТЬ** *несов.* — ныгый төшү, тазара төшү, көчәя төшү.

**КРЕ'ПОВЫЙ** — креп..., крептан ясалган; *креповая повязка* — креп бәйләвеч.

**КРЕПОСТНИ'К** *м. публиц.* — крепостник, крепостной правоны яклаучы.

**КРЕПОСТНИ'ЧЕСКИЙ** — крепостник...-ы; крепостниклык...-ы; *крепостнические взгляды* — крепостниклык карашлары.

**КРЕПОСТНИ'ЧЕСТВО** *ср. мн.* нет — 1. крепостнойлык; 2. крепостник карашлары.

**КРЕПОСТНО'Й** I — крепостной; *крепостное хозяйство* — крепостной хуҗалык; *крепостной крестьянин* — крепостной крестьян. ◇ **Крепостное право** — крепостной право (алпавытның крепостной крестьяннар белән теләгәнчә эш итүгә хокуклы булуы).

**КРЕПОСТНО'Й** II — крепость...-ы; *крепостная артиллерия* — крепость артиллериясе.

**КРЕ'ПОСТЬ** I *ж. мн.* нет — 1. ныклык, тазалык, чыдамлылык, түземлелек; 2. катылык, куелык.

**КРЕ'ПОСТЬ** II *ж.* — крепость, ныгытма.

**КРЕ'ПОСТЬ** III *ж. доревол.* — (берәр нәрсәне) биләүгә хокук документы; *совершать крепость на дом* — йортны биләүгә хокук документы булдыру.

**КРЕПЧА'ТЬ** *несов. разг.* — көчәю, куәтләнү.

**КРЕ'ПЧЕ** — 1. ныграк, чыдамлырак; *сталь крепче железа* — корыч тимердән ныграк; 2. көчлерәк, тазарак; *он крепче меня* — ул миннән көчлерәк (тазарак); 3. катырак, куерак.

**КРЕПЫ'Ш** *м. разг.* — таза кеше, нык кеше.

**КРЕПЬ** I *ж. простореч. устар.* — крепостной хокук.

**КРЕПЬ** II *ж. тех.* — ныгытма, ныгыту корылмасы (шахталарда).

**КРЕСА'ЛО** *ср. обл. устар.* — чакма ташы.

**КРЕ'СЕЛЬНЫЙ** — кресло...-ы; *кресельная ручка* — кресло култыксасы.

**КРЕ'СЛО** *ср.* — кресло (култыксалы, таянчыклы урындык).

**КРЕСТ** *м.* — 1. тәре, тәре рәсеме, хач; 2. *перен.* авыр язмыш, интегү; *это — мой крест* — бу—минем авыр язмышым, интегүләрем. ◇ **Общество Красного креста** — Кызыл хач җәмгыяте. **Поставить крест** — өмет өзү, булмаганга, беткәнгә исәпләү. **Крест-на-крест** — аркылы-торкылы.

**КРЕСТЕ'Ц** *м.* — 1. оча башы сөяге, койрык төбе сөяге, эвернә сөяк; 2. *обл.* кырлы чүмәлә.

**КРЕСТИ'ТЬ** *несов.* — 1. *рел.* чукындыру; 2. *разг. устар.* сызгалап ташлау.

**КРЕСТИ'ТЬСЯ** *несов.* — чукыну.

**КРЕСТОВИ'К** *м. зоол.* — агулы үрмәкүч.

**КРЕСТОВИ'НА** *ж.* — 1. эвернә (бер-беренә аркылы куеп ныгытылган ике агач); 2. *ж.-д.* крестовина (рельслы юлларда бер юлдан икенче юлга күчерү җайланмасы).

**КРЕСТОЦВЕ'ТНЫЕ** *бот.* — эвернә чәчәкләләр.

**КРЕСТЬЯ'НИН** *м.* (*мн.* крестьяне) — крестьян.

**КРЕСТЬЯ'НКА** *ж.* — крестьян хатын-кызы.

**КРЕСТЬЯ'НСКИЙ** — крестьян...-ы; крестьяннар ... -ы; *крестьянский двор* — крестьян йорты; *крестьянское движение* — крестьяннар хәрәкәте.

**КРЕСТЬЯ'НСТВО** *ср. мн.* нет — 1. крестьяннар; 2. *устар.* игенчелек, крестьян хезмәте; *заниматься крестьянством* — игенчелек белән шөгыльләнү.

**КРЕСТЬЯ'НСТВОВАТЬ** *несов. обл.* — иген игү, игенчелек белән шөгыльләнү.

**КРЕТИ'Н** *м.*, **КРЕТИ'НКА** *ж.* — 1. кретинизм белән авыручы; 2. *перен.* аңгыра, идиот.

**КРЕТИНИ'ЗМ** *м. мн.* нет — кретинизм (1. *мед.* калкансыман бизнең үсмәве сәбәпле була торган авыру, физик һәм акыл ягыннан зәгыйфьлек; 2 *перен. бран.* аңгыралык, идиотлык).

**КРЕТО'Н** *м.* — кретон (буяулы җептән эшләнгән тыгыз мамык тукыма).

**КРЕТО'ННЫЙ, КРЕТО'НОВЫЙ** — кретон..., кретоннан ясалган; *кретоновая обивка* — кретон тышлык.

**КРЕ'ЧЕТ** *м. зоол.* — карчыга (ның бер төре).

**КРЕЩЕ'НИЕ** *ср. рел.* — (*обряд*) чукындыру, чукыну (христиан динен кабул итүчеләр йоласы). ◇ **Боевое крещение** — 1. беренче башлап сугышка катнашу; 2. берәр эшне беренче башлап үтәү, чиркәнчек алу.

**КРИВА'Я** *мат.* — кәкре, кәкре сызык.

**КРИ'ВДА** *ж. мн.* нет, *обл. нар.-поэт.* — кыңгыр эш, ялган.

**КРИВЕ'ТЬ** *несов. простореч.* — сукыраю (бер күзе).

**КРИВИЗНА'** *ж.* — 1. кәкрелек, чалышлык, кыйшыйлык; 2. кәкрәйгән урын, чалышайган урын.

**КРИВИ'ТЬ** *несов.* — кәкрәйтү, кыегайту, чалышайту, кыйшайту, кыңгырайту. ◇ **Кривить душой** — алдашу, ялганлау, ялган сөйләү.

**КРИВИ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. кәкрәю, кыегаю, чалышаю, кыйшаю, кыңгыраю; 2. *перен. разг. фам.* чырай бозу, йөз чыту, чырай сыту.

**КРИВЛЯ'КА** *м.* и *ж. разг. фам.* — кыланчык кеше.

**КРИВЛЯ'ТЬСЯ** *несов. разг.* — боргалану-сыргалану, кылану.

**КРИ'ВО** *нареч.* — кыегайтып, чалышайтып, кыек итеп, чалыш итеп.

**КРИВОБО'КИЙ** — кәкре гәүдәле.

**КРИВОГЛА'ЗЫЙ** — бер күзе сукыр кеше, сыңар күзле кеше.

**КРИВОДУ'ШИЕ** *ср. мн.* нет, *устар.* — эчкерлелек, вөҗдансызлык.

**КРИВОДУ'ШНИЧАТЬ** *несов. устар.* — эчкерлеләнү, вөҗдансыз эш итү.

**КРИВОДУ'ШНЫЙ** *устар.* — эчкерле, вөҗдансыз.

**КРИВО'Й** — 1. кәкре, чалыш, кыңгыр, кыйшык; 2. *разг.* сукыр (бер күзе), сыңар күзле; 3. *перен.* ялган, хаксыз. ◇ **Кривая вывезет, вывезла** *простореч.* — көтелмәгән берәр хәл ярдәм итәр (итте). **На кривой не объедешь** *простореч.* — бер төрле хәйлә белән дә алдый алмассың. **Кривое зеркало** — 1. начар көзге, ялгыш күрсәтә торган көзге; 2. *перен.* берәр нәрсәне бозып сурәтләү. **Кривая улыбка или усмешка** — нәфрәтләнәп елмаеп кую.

**КРИВОКОЛЕ'ННЫЙ** *спец.* — текә борылышлы (тыкрык, урам).

**КРИВОЛА'ПЫЙ** *разг.* — кәкре аяклы.

**КРИВОЛИНЕ'ЙНЫЙ** *мат.* — кәкре сызыклы.

**КРИВОНО'ГИЙ** *разг.* — кәкре аяклы.

**КРИВОНО'СЫЙ** *разг.* — кәкре борынлы.

**КРИВОРО'ТЫЙ** — чалыш авызлы.

**КРИВОТО'ЛКИ** *ед.* нет — төпсез хәбәрләр, имеш-мимешләр, ялган хәбәрләр.

**КРИВОШЕ'ИЙ** — кәкре муенлы.

**КРИВОШЕ'Я** *ж. мн.* нет, *мед.* — кәкре муенлылык, кыек башлылык.

**КРИВОШИ'П** *м. тех.* — кривошип (машина валын әйләндерә торган көянтә, рычаг).

**КРИ'ЗИС** *м.* — кризис (1. кискен үзгәреш, мәсәләң, авыруның хәлен яхшыртуга яки начарлатуга алып бара торган кискен үзгәреш; 2. *экон.* капиталистик экономикада товарны чагыштырмача артык җитештерү һәм массаның сатып алу сәләте кимү аркасында производствоны кыскартуга яки бөтенләй бетерүгә һәм эшсезләрнең санын арттыруга алып бара торган һәм периодик кабатланып тора торган күренеш; 3. *полит.* капиталистик илләрдә политик хәлнең кискенләшүе; 4. *разг. шутл.* акчасызлык, кыен хәл).

**КРИК** *м.* — 1. тавыш, каты тавыш, кычкыру тавышы, аваз; 2. җикерү, җикеренү, җикереп кычкыру, акыру, акырыну. ◇ **Последний крик моды** — иң соңгы мода.

**КРИКЛИ'ВО:** **крикливо одеваться** — күзгә бәрелеп торырлык итеп киенү.

**КРИКЛИ'ВЫЙ** — 1. ачы, каты, үткен; *крикливый голос* — ачы тавыш; 2. ачы тавышлы, каты тавышлы, каңгылдаучан; *крикливые гуси* — каңгылдаучан казлар; 3. кычкырып сөйләүчән, кычкырырга яратучан; мыгырдаучан, җикеренүчән, ызгыштиргәш яратучан; 4. *перен.* кычкырып тора торган, күзгә ташланып тора торган; *крикливая реклама* — кычкырып тора торган реклама.

**КРИ'КНУТЬ** *однокр. сов.* — кычкырып җибәрү, кычкырып кую, кычкыру.

**КРИ'КСА** *м.* и *ж. простореч. обл.* — 1. *ж.* бертуктаусыз сыкранып елап тору (бала турында); 2. *м.* и *ж.* елак бала.

**КРИКУ'Н** *м.*, **КРИКУ'НЬЯ** *ж. разг.* — 1. кычкыручан кеше; ачы тавышлы кеше; 2. *перен. пренебр.* буш бугаз, лыгырдык.

**КРИМИНА'Л** *м. разг.* — криминал, җинаятьле эш.

**КРИМИНАЛИ'СТ** *м.* — криминалист (1. криминалистика белгече; 2. җинаять эшләре буенча адвокат-белгеч).

**КРИМИНАЛИ'СТИКА** *ж. мн.* нет — криминалистика (хокук фәненең җинаятьләрне тикшерү методларын өйрәнә торган бүлеге).

**КРИМИНА'ЛЬНЫЙ** *книж.* — җинаять...-ы, җинаятьчел; *криминальный случай* — җинаятьчел вакыйга.

**КРИМИНОЛО'ГИЯ** *ж. мн.* нет — криминология (җинаятьне социаль күренеш булу ягыннан өйрәнү).

**КРИН** *м. книж. поэт. устар.* — лалә (чәчәге).

**КРИ'НКА** *ж.* — к. крынка.

**КРИПТОГРАФИ'ЧЕСКИЙ** *филол.* — криптографик; *криптографическое письмо* — криптографик язу.

**КРИПТОГРА'ФИЯ** *ж. мн.* нет — криптография, шартлы язма, яшерен язу.

**КРИСТА'ЛЛ** *м.* — кристалл; *кристаллы соли* — тоз кристаллары.

**КРИСТАЛЛИЗА'ТОР** *м. спец.* — кристаллизатор (химик кушылмаларны кристаллаштыру приборы).

**КРИСТАЛЛИЗАЦИО'ННЫЙ** *книж. спец.* — кристаллаштыру...-ы; *кристаллизационный аппарат* — кристаллаштыру аппараты.

**КРИСТАЛЛИЗИ'РОВАТЬ, КРИСТАЛЛИЗОВА'ТЬ** *сов.* и *несов. спец.* — кристалларга әвереләдерү, кристаллаштыру.

**КРИСТАЛЛИЗИ'РОВАТЬСЯ, КРИСТАЛЛИЗОВА'ТЬСЯ** *сов.* и *несов.* — 1. кристалларга әверелү, кристаллар формасын алу, кристаллашу; 2. *перен. книж.* кристаллашып килү (тотрыклы хәлгә керү, формалашып килү); *кристаллизуются новые формы быта* — көнкүрешнең яңа формалары кристаллашып килә.

**КРИСТАЛЛИ'ЧЕСКИЙ** — 1. кристалл...-ы; кристаллык...-ы; *кристаллическое состояние* — кристаллык торышы; 2. кристаллик, кристаллардан тора торган; *кристаллическая структура металлов* — металларның кристаллик структурасы.

**КРИСТАЛЛИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *науч.* — кристаллик төзелеш.

**КРИСТАЛЛО'ГРАФ** *м.* — кристаллограф, кристаллография белгече.

**КРИСТАЛЛОГРА'ФИЯ** *ж. мн.* нет — кристаллография (кристалларның төзелеше һәм формалары турындагы фән).

**КРИСТА'ЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет — сафлык, чисталык, пакьлек, саф күңеллелек.

**КРИСТА'ЛЬНЫЙ** — 1. кристалл...-ы; *кристальная форма* — кристалл формасы; 2. *перен.* үтә күренә торган; *кристальная вода* — үтә күренә торган су; 3. *перен.* саф, пакь, саф күңелле; *кристально-чистый человек* — саф күңелле кеше.

**КРИТЕ'РИЙ** *м. книж.* — критерий (берәр нәрсәгә бәя бирү өчен, төркемләү өчен нигез булып тора торган билге).

**КРИТЕ'РИУМ** *м. книж. устар.* — к. критерий.

**КРИ'ТИК** *м.* — критик, тәнкыйтьче, тәнкыйть итүче.

**КРИ'ТИКА** *ж.* — критика, тәнкыйть; кимчелекләрне күрсәтү.

**КРИТИКА'Н** *м.*, **КРИТИКА'НКА** *ж. неодобр.* — бәйләнчек кеше, гаеп эзләүче.

**КРИТИКА'НСТВО** *ср. мн.* нет — бәйләнчеклек, урынсыз тәнкыйть.

**КРИТИКА'НСТВОВАТЬ** *несов. неодобр.* — урынсыз тәнкыйтьләү, урынсыз тәнкыйть белән шөгыльләнү.

**КРИТИКОВА'ТЬ** *несов.* — тәнкыйтьләү, тәнкыйть итү, кимчелекләрне күрсәтү.

**КРИТИКОВА'ТЬСЯ** *несов.* — тәнкыйтьләнү, тәнкыйть ителү.

**КРИТИЦИ'ЗМ** *м. мн.* нет — критицизм (1. тәнкыйтьле караш, тәнкыйть белән карау; 2. „критик" философия, ягъни кантчылык һәм реакцион, идеалистик философияләнең аңа иярә торган агымнары).

**КРИТИ'ЧЕСКИ** *нареч.* — тәнкыйть күзлегеннән карап.

**КРИТИ'ЧЕСКИЙ** I — 1. критика...-ы; тәнкыйть...-ы; *критический отдел в журнале* — журналда тәнкыйть бүлеге; 2. тәнкыйтьчел, тәнкыйтькә сәләтле; *критический ум* — тәнкыйтьчел акыл.

**КРИТИ'ЧЕСКИЙ** II — 1. кискен, критик; *критический момент* — кискен момент; 2. бик кыен, куркыныч; *критическое положение* — куркыныч хәл.

**КРИТИ'ЧНО** *нареч.* — тәнкыйть күзлегеннән карап.

**КРИТИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет — тәнкыйтьчеллек.

**КРИТИ'ЧНЫЙ** — тәнкыйтьчел.

**КРИЧА'ТЬ** *несов.* — 1. кычкыру, акыру; аваз салу; *дети кричат* — балалар кычкыра; 2. *простореч.* кычкырып чакыру, дәшү; 3. (*бранить*) акырыну, җикеренү, кычкыру.

**КРИЧА'ЩИЙ** — 1. кычкыра торган, кычкыручы, акыручы; 2. *перен.* күзгә бәрелеп тора торган.

**КРОВ** *м. мн.* нет — 1. *устар.* түбә, өй түбәсе; 2. *поэт.* пәрдә, каплама; *под кровом ночи* — төн пәрдәсе астында; 3. *поэт.* и *ритор.* өй, торак, тору урыны, сыеныр урын.

**КРОВА'ВИТЬ** *несов.* — канга батыру, канга буяу.

**КРОВАВОКРА'СНЫЙ** *книж.* — җете кызыл, кан кебек кызыл.

**КРОВА'ВЫЙ** — 1. кан...-ы; кан кебек кызыл; *кровавый цвет* — кан төсе; 2. канлы, канга буялган; *кровавые руки* — канлы куллар; 3. канлы, кан белән тулган; *кровавая опухоль* — канлы шеш; *кровавая битва* — канлы сугыш; 4. канечкеч; *кровавый враг* — канечкеч дошман.

**КРОВА'ТКА** *ж. разг.* — кечкенә кровать.

**КРОВА'ТНЫЙ** — кровать...-ы; *кроватное производство* — кровать производствосы.

**КРОВА'ТЬ** *ж.* — кровать.

**КРО'ВЕЛЬНЫЙ** — түбә...-ы; түбә ябу...-ы; *кровельное железо* — түбә калае; *кровельные работы* — түбә ябу эшләре.

**КРО'ВЕЛЬЩИК** *м. спец.* — түбә ябучы.

**КРОВЕНО'СНЫЙ** — кан...-ы; кан йөреше...-ы; *кровеносный сосуд* — кан тамыры; *кровеносная система* — кан йөреше системасы.

**КРОВИ'НКА** *ж.* — кан тамчысы. ◇ **Ни кровинки в лице** — йөзендә кан әсәре калмаган; чырае качкан, ап-ак булган.

**КРО'ВЛЯ** *ж.* — 1. түбә, өй түбәсе, караты түбәсе; 2. түбә аслыгы, түбә астары. ◇ **Под кровлей** — өйдә, торакта.

**КРО'ВНО** *нареч.* — 1. туганлык ягыннан, кардәшлек ягыннан; *кровно связан* — кардәшлек ягыннан бәйләнгән; 2. бик нык; *я кровно заинтересован* — мин бик нык кызыксынам (минем өчен әһәмияте бик зур); *кровно оскорбить* — бик нык мыскыл итү.

**КРО'ВНЫЙ** — 1. ата ягыннан; *кровное родство* — ата ягыннан кардәшлек; 2. туганлык...-ы; *кровное чувство* — туганлык тойгысы; 3. кардәшлек...-ы; *кровная связь* — кардәшлек бәйләнеше; 4. нәселле, яхшы нәселле; *кровный рысак* — нәселле юртак ат; 5. иң кирәкле; *кровное дело* — иң кирәкле эш; 6. аяусыз, каты; *кровная обида* — аяусыз кыерсыту, аяусыз кыерсытылу. ◇ **Кровные деньги** — үз көче бе-

лән (үз хезмәте белән) тапкан акча. Кровный враг — кан дошманы, иң явыз дошман.

**КРОВОЖА'ДНОСТЬ** *ж. мн.* нет — аяусызлык, кансызлык.

**КРОВОЖА'ДНЫЙ** — канечкеч, канга сусаган, аяусыз, усал.

**КРОВОИЗЛИЯ'НИЕ** *ср. мед.* — кан йөгерү, кан саву, кан бәрү; *кровоизлияние в мозг* — мигә кан бәрү.

**КРОВООБРАЩЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — кан йөреше, кан әйләнеше.

**КРОВООСТАНА'ВЛИВАЮЩИЙ** — кан туктата торган.

**КРОВООЧИЩЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *мед. устар.* — күрем, менструация.

**КРОВОПИ'ВЕЦ** *м. простореч. обл.*, **КРОВОПИ'ЕЦ** *м. простореч.* — к. кровопийца.

**КРОВОПИ'ЙСТВО** *ср. мн.* нет, *книж. устар.* — аяусызлык, шәфкатьсезлек, рәхимсезлек, кансызлык.

**КРОВОПИ'ЙЦА** *м.* — аяусыз кеше, канечкеч кеше, рәхимсез кеше.

**КРОВОПОДТЁК** *м.* — кан йөгерү, кан саву, кан җыйналу, кан төйнәлү (бәрелү, сугылудан).

**КРОВОПРОЛИ'ТИЕ** *ср. книж.* — кан кою, кан коеш, кан түгү, үтереш.

**КРОВОПРОЛИ'ТНЫЙ** *книж.* — канкойгыч; *кровопролитное сражение* — канкойгыч сугыш.

**КРОВОПУСКА'НИЕ** *ср.* — 1. *мед.* кан алдыру; 2. *перен. презр.* масса күләмендә үтереш, күпләп үтереш, кан кою (буржуаз илләрдә полициянең хезмәт ияләрен аяусыз әзәрлекләвенә карата әйтелә).

**КРОВОСО'С** *м.* — 1. *зоол.* Америка ярканаты; 2. *простореч.* к. кровопийца; 3. *обл.* (*упырь*) убыр, өрәк.

**КРОВОТЕЧЕ'НИЕ** *ср. мед.* — кан агу, кан китү.

**КРОВОТОЧИ'ВЫЙ** *книж.* — 1. *устар.* кан китү белән җәфаланучы; 2. *мед.* кан агып тора торган, кан саркып тора торган (мәсәлән, яра).

**КРОВОТОЧИ'ТЬ** *несов. мед.* — канау, кан агып тору.

**КРОВОХА'РКАТЬ** *несов. мед.* — кан төкерү, кан какыру.

**КРО'ВУШКА** *ж. мн.* нет, *простореч.* — кан.

**КРОВЬ** *ж.* — 1. кан; 2. *перен.* (*убийство*) үтереш, үтерү; 3. (*единокровное родство*) кан кардәшлеге, якын кардәшлек, туганлык; 4. *только мн. простореч.* күрем, менструация. ◇ Ведь ты казак по крови, по дедам — син казак баласы лабаса, синең ата-бабаларың казак булган лабаса. Портить кровь *разг.* — кан бозу, ачуландыру. Пролить кровь (свою) *ритор.* — кан кою, һәлак булу. Пролить кровь *чью* — кеше канын кою; үтерү. Пить кровь *чью ритор.* — кан эчү, җәфалау, эксплуатацияләү. Кровь с молоком *разг.* — чиртсәң каны чыгар (таза, алсу йөзле кеше турында). Плоть и кровь *устар.* — туган балам. Кровь ударила или бросилась в голову *перен.* — бик нык ярсыдым.

Писать кровью *книж. перен.* — чын күңелдән язу.

**КРОВЯНИ'СТЫЙ** — канлы; *кровянистое мясо* — канлы ит.

**КРОВЯНИ'ТЬ** *несов. простореч.* — канга буяу, канга пычрату.

**КРОВЯНО'Й** — 1. кан...-ы; *кровяные шарики* — кан тәнчекләре; 2. канлы, каннан ясалган; *кровяное удобрение* — канлы ашлама; 3. кан төсле, кызыл.

**КРОЁНЫЙ** — киселгән, кисеп хәзерләнгән (кием тегәр өчен).

**КРОИ'ЛЬНЫЙ** — кием кисү...-ы; *кроильный стол* — кием кисү өстәле.

**КРОИ'ТЬ** *несов.* — кисү (кием, аяк киеме тегү өчен материяне, күнне).

**КРОИ'ТЬСЯ** *несов.* — киселү (материя, күн).

**КРОЙ** *м. порт.* — 1. өлге (кием кисү өчен); 2. кием кисү.

**КРО'ЙКА** *ж. мн.* нет — кием кисү, аяк киеме кисү.

**КРОКЕ'Т** *м. спорт.* — крокет (шарларны кечкенә капкаларга кертеп уйный торган уен).

**КРОКИ'** *ср. нескл.* — кроки (өстән-өстән генә эшләнгән план, рәсем, чертёж).

**КРОКИ'РОВА'ТЬ** *сов.* и *несов.* — крокировать итү (крокет уйнаганда үз шарың белән башка кеше шарына бәрдерү).

**КРОКОДИ'Л** *м.* — крокодил.

**КРОКОДИ'ЛОВЫЙ** — крокодил...-ы; *крокодиловая кожа* — крокодил тиресе. ◇ Крокодиловы слёзы — юри елау, ясалма елау, елаган булып кылану.

**КРО'ЛИК** *м.* — 1. кролик, йорт куяны; 2. *разг.* кролик мехы.

**КРОЛИКОВО'Д** *м.* — кроликлар үрчетүче.

**КРОЛИКОВО'ДСТВО** *ср.* — 1. кроликлар үрчетү; 2. кроликлар үрчетү хуҗалыгы.

**КРОЛИКОВО'ДЧЕСКИЙ** — кроликлар үрчетү...-ы; *кролиководческое хозяйство* — кроликлар үрчетү хуҗалыгы.

**КРО'ЛИКОВЫЙ, КРО'ЛИЧИЙ** — кролик...-ы; *кроличье мясо* — кролик ите.

**КРОЛЬЧА'ТНИК** *м.* — 1. кроликлар үрчетү хуҗалыгында эшләүче; 2. кроликлар үрчетү бинасы; 3. кроликлар үрчетү хуҗалыгы.

**КРОЛЬЧИ'ХА** *ж.* — ана кролик.

**КРО'МЕ** *предлог* — 1. ...-дан башка, ...-дан бүтән; *кроме него никого не видел* — аннан башка беркемне дә күрмәдем; 2. ...-дан тыш, ...-ның өстенә; *кроме оклада получил подъёмные* — хезмәт хакыннан тыш подъёмный акчасы алдым. ◇ Кроме шуток — чыннан да; *кроме шуток, я хочу уехать отсюда* — чыннан да, мин биредән китәргә уйлыйм.

**КРОМЕ'ШНЫЙ** *устар.* — авыр, читен, кыен. ◇ Тьма кромешная — дөм-караңгылык. Ад кромешный *разг.* — ыгы-зыгы, чуалчыклык; өзлексез талашлар, шау-шу, ызгыш.

**КРО'МКА** *ж.* — кырый, чит; *кромка льда* — боз чите.

**КРОМСА'ТЬ** *несов. разг.* — 1. ботарлау, кисkәләү, тураклау; 2. *перен.* кисәкләп (вак-лап) бозу, вак кисәкләргә бүлгәләп бозу.

**КРО'НА I** *ж.* — (*верхняя часть дерева*) ябалдаш.

**КРО'НА II** *ж.* — крона (кайбер Көнбатыш Европа илләрендә акча берәмлеге).

**КРОНГЛА'С** *м. тех.* — кронглас (оптик приборлар өчен махсус пыяла).

**КРО'НИСТЫЙ** — зур ябалдашлы; *кронистая яблоня* — зур ябалдашлы алмагач.

**КРОНЦИ'РКУЛЬ** *м.* — кронциркуль (бик кечкенә түгәрәкләр сызу өчен кулланыла торган циркуль).

**КРОНШТЕ'ЙН** *м.* — кронштейн (берәр нәрсәне, мәсәлән, балконны терәтү өчен стенага беркетелгән терәк).

**КРО'ПАТЬ** *несов. разг.* — 1. әкрен маташу, акрын кыймылдау, әкрен кайнашу, белер-белмәс эшләү; 2. начар язу, белер-белмәс язып маташу (начар әдәби әсәрләр язу турында).

**КРОПИ'ТЬ** *несов.* — 1. бөркеп чылату, сибәләп чылату; 2. сибәләп яву, пыскаклап яву, сибәләп тору; *целый день кропил дождь* — көне буе яңгыр сибәләп торды; 3. *церк.* „изге" су бөркү.

**КРОПИ'ТЬСЯ** *несов.* — бөркеп чылатылу, сибәләп чылатылу.

**КРОПОТЛИ'ВО** *нареч.* — тырышып, төпченеп, басылып; *кропотливо работать* — басылып эшләү.

**КРОПОТЛИ'ВОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. тырышлык, басылып эшләүчәнлек; 2. күп көч сорау, күп түземлек сорау; *кропотливость работы* — эшнең күп көч соравы.

**КРОПОТЛИ'ВЫЙ** — 1. тырыш, төпченүчән, җентекләүчән, басылып эшләүчән; 2. күп көч таләп итә торган, тырышлык таләп итә торган, басылып эшләүне таләп итә торган.

**КРОПОТНЯ'** *ж. мн.* нет, *обл.*— четерекле эш, матавыклы эш, эч пошыргыч вак эш.

**КРОПОТУ'Н** *м.*, **КРОПОТУ'НЬЯ** *ж.* — әкрен кыймылдаучан, вак-төяккә игътибар бирүчән кеше.

**КРО'СНО** *ср. обл.* — туку станогы.

**КРОСС** *м.* — кросс (1. *спорт.* таулы-чокырлы, юлсыз урыннарда йөгереш; 2. бокста — каршы якның сугарга дип күтәргән кулын сугып төшерү).

**КРОТ** *м. зоол.* — 1. сукыр тычкан; 2. сукыр тычкан мехы.

**КРО'ТКИЙ** — юаш, басынкы, сабыр, инсафлы.

**КРОТО'ВЫЙ** — сукыр тычкан...-ы; *кротовая шкура* — сукыр тычкан тиресе; 2. сукыр тычкан мехыннан тегелгән.

**КРО'ТОСТЬ** *ж. мн.* нет — юашлык, басынкылык, сабырлык, инсафлылык.

**КРОХА'** *ж.* — валчык, бөртек.

**КРО'ХИ** *мн. перен. пренебр.*—калдык-постыклар, сынык-саныклар, кисәк-косаклар.

**КРОХОБО'Р** *м. разг. пренебр.* — крохобор (1. вакчыл кеше, вак-төякләргә зур әһәмият бирүче кеше; 2. үз фәненең вак мәсьәләләре өстендә генә чокчынып маташучы галим).

**КРОХОБО'РСКИЙ** *разг. пренебр.* — крохоборлык...-ы, крохоборларча; *крохоборское отношение к фактам* — фактларга крохоборларча мөнәсәбәт.

**КРОХОБО'РСТВО** *ср. мн.* нет, *разг. пренебр.* — крохоборлык.

**КРОХОБО'РСТВОВАТЬ** *несов. разг. пренебр.*— крохоборлык белән шөгыльләнү.

**КРО'ХОТНЫЙ** *разг. фам.*— бик кечкенә, бик вак, валчыктай гына.

**КРО'ШЕВО** *ср. обл.* — 1. турама (төрле азыклардан турап хәзерләнгән ашамлык); 2. *перен. разг.* корама, кырык-корама (төрле вак предметлар, күренешләр кушылмасы).

**КРО'ШЕНЫЙ** — валчыклардан тора торган, вак кисәкләрдән тора торган.

**КРО'ШЕЧКА** *ж. разг. фам.* — аз гына, кечкенә генә, чеметем генә; *дай крошечку хлебца* — әз генә икмәк бирче; *ни крошечки не понял* — әз генә дә аңламадым; бер тамчы да аңламадым.

**КРО'ШЕЧНЫЙ** *разг.* — бик кечкенә, кечкенә генә, валчыктай гына.

**КРОШИ'ЛЬЩИК** *м. спец.* — тураклаучы, тураучы (эшче).

**КРОШИ'ТЬ** *несов.*— 1. (*ломать на крошки*) турау, тураклау, ваклау; 2. *разг.* чүпләү; *не кроши на пол* — идәнне чүпләмә; 3. *перен. разг.* (*истреблять во множестве*) тар-мар итү, кыру, тураклау.

**КРОШИ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. кителү, ваклану; *зубы крошатся* — тешләрем кителә; 2. *страд.* туралу, тураклану, ваклану.

**КРО'ШКА I** *ж. разг.* — 1. валчык; *крошка хлеба* — икмәк валчыгы; *мраморная крошка* — мәрмәр валчыгы, вакланган мәрмәр; 2. (*малютка*) балакаем, үскәнем, иркәм, бәгърем. ◇ Крошку — аз гына; *подумайте хоть крошку* — аз гына булса да уйлап карагыз. Ни крошки — аз гына да, бер дә, һич тә; *ни крошки не испугался* — аз гына да курыкмадым, тамчы да курыкмадым. Нет ни крошки масла — бер генә тамчы да май юк.

**КРО'ШКА II** *ж. мн.* нет — 1. турау, тураклау, ваклау; 2. туралган сорт; *табак мелкой крошки* — вак туралган тәмәке (тәмәкенең вак туралган сорты).

**КРУГ** *м.* — 1. *мат.* түгәрәк; 2. *перен. книж.* чик; *круг развития* — үсеш чиге; 3. ара, эч; *в кругу друзей* — дуслар арасында; *решили обсудить это в семейном кругу* — моны семья эчендә тикшерергә карар бирдек; 4. *только мн. книж.* даирәләр; *в кругах, близких к министерству* — министрлыкка якын даирәләрдә. ◇ На круг *разг.* — уртача, якынча; *на круг вышло по 200 рублей в месяц* — уртача айга 200 сум туры килде. Порочный круг— 1. берәр положениене үзе исбат ителүне сорый торган икенче бер положение белән исбат итү; 2. *перен.* котылу юлы булмаган кыен хәл, котылгысыз хәл.

**КРУ'ГЛЕНЬКИЙ** *разг. фам.* — түгәрәк кенә, йоп-йомры, түп-түгәрәк; таза гына,

тулы гына. ◇ **Кругленькая сумма** *разг. фам.* — шактый зур сума (акча).

**КРУГЛЕ'ТЬ** *несов. разг.* — түгәрәкләнү, түгәрәкләнә бару, түгәрәкләнә төшү, йомрылану.

**КРУГЛИ'ТЬ** *несов. спец.* — түгәрәкләү, түгәрәкләндерү, түгәрәк формага кертү.

**КРУГЛИ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. түгәрәкләнү; 2. (*виднеться — о круглых предметах*) түгәрәкләнеп күренү, түгәрәкләнеп тору; 3. *страд.* түгәрәкләндерелү.

**КРУГЛОГОЛО'ВЫЙ** *разг.* — түгәрәк башлы, йомры башлы.

**КРУГЛОГУ'БЦЫ** *ед.* нет, *тех.* — каргаборын (келәшчәнең бер төре).

**КРУГЛОЛИ'ЦЫЙ** — түгәрәк йөзле.

**КРУГЛОЛИ'ЧКА** *ж. нар.-поэт.* — түгәрәк йөзле кыз, түгәрәк йөзле хатын.

**КРУГЛОСУ'ТОЧНЫЙ** *книж.* — тәүлек буена сузыла торган.

**КРУГЛОТА'** *ж. мн.* нет, *простореч.* — түгәрәклек, йомрылык.

**КРУ'ГЛЫЙ** — 1. түгәрәк; *круглый стол* — түгәрәк өстәл; 2. йомры; *круглая лампочка* — йомры лампочка; 3. *перен.* шыр, чепчи, бөтенләй; *круглый дурак* — шыр тиле; *круглое невежество* — чеп-чи наданлык; 4. тулы; *в круглых цифрах* — тулы цифрларда алганда. ◇ **Круглый год** — ел буе, ел буена, ел тәүлеге. **Круглые сутки** — тәүлек буе, тәүлек буена. **Круглый сирота** — тулы ятим, үксез бала, әтисез-әнисез бала.

**КРУГЛЫ'Ш** *м. обл.* — йомры таш, чуерташ.

**КРУГЛЯ'К** *м.* — 1. *обл.* к. круглыш; 2. *спец.* йомры кискә, йомры түмәркә, бүкән.

**КРУГОВО'Й** — әйләнүле, әйләнмәле, түгәрәк буенча...; *круговое движение* — әйләнүле хәрәкәт, түгәрәк буенча хәрәкәт. ◇ **Круговая порука** — берсен-берсе яклау.

**КРУГОВОРО'Т** *м. мн.* нет, *книж.* — 1. өзлексез хәрәкәт, өзлексез әйләнеп тору; *круговорот воды на земле* — суның җир өстендә өзлексез хәрәкәте; 2. өзлексез үзгәреп тору; *круговорот событий* — вакыйгаларның өзлексез үзгәреп торуы.

**КРУГОВРАЩА'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.* — түгәрәк тирәли, түгәрәк ясап ...; *кругоВращательное движение* — түгәрәк ясап хәрәкәт итү.

**КРУГОВРАЩЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — 1. түгәрәк ясап хәрәкәт итү, тирәли хәрәкәт итү; 2. к. круговорот.

**КРУГОЗО'Р** *м. книж.* — 1. *устар.* күз күреме, горизонт; 2. *перен.* белем, белем дәрәҗәсе; *учёный с узким кругозором* — сай белемле галим.

**КРУ'ГОМ** *нареч.*: **голова идёт кругом** — башым катты, башым катып бетте, башым әйләнде.

**КРУГО'М** — 1. *нареч.* түгәрәк ясап; 2. *воен.* (*команда*) кругом; 3. *нареч.* әйләнә-тирәдә; *кругом нет ни лесов, ни гор* — әйләнә-тирәдә урманнар да, таулар да юк; 4. *разг.* бөтенләй, тулысынча, һәрьяклап; *кругом виноват* — бөтенләй гаепле, һәр яктан гаепле; 5. *предлог с род. п.* тирәсендә, әйләнәсендә; *кругом дома бродили собаки* — өй тирәсендә этләр әрле-бирле йөриләр иде.

**КРУГООБОРО'Т** *м. книж.* — әйләнеш; *кругооборот капитала* — капитал әйләнеше (капиталның акчадан товарга һәм товардан акчага әйләнүе).

**КРУГООБРА'ЗНЫЙ** *книж.* — түгәрәксыман, түгәрәккә охшаган.

**КРУГОСВЕ'ТНЫЙ** — җир шары тирәли; җир шарын әйләнеп чыгу...-ы; *кругосветное путешествие* — җир шары тирәли сәяхәт.

**КРУЖА'ЛО** *ср.* — 1. кружало (а. таш гөмбәзләр салганда куллану өчен такталардан дугасыман итеп ясалган җайланма; б. *спец.* чүлмәк ясаганда кулланыла торган түгәрәк); 2. *истор.* трактир, кабак.

**КРУЖЕВА'** *мн.* (*ед.* кружево) — челтәр.

**КРУЖЕВНИ'ЦА** *ж. спец.* — челтәр бәйләү остасы, челтәр бәйләүче.

**КРУЖЕВНО'Й** — 1. челтәр бәйләү...-ы; *кружевная мастерская* — челтәр бәйләү мастерское; 2. челтәр...; *кружевной воротник* — челтәр яка.

**КРУЖИ'ТЬ** *несов.* — 1. әйләндерү, әйләндереп йөртү, бөтерелдерү; 2. әйләнү, әйләнеп йөрү; *ястреб кружил над цыплятами* — карчыга чебешләр турында әйләнеп йөри иде; 3. адашып йөрү, юл язып йөрү; *кружить по лесу* — урманда адашып йөрү; 4. (*заставлять блуждать*) адаштырып йөртү; 5. (*взметать пыль, снег*) туздыру, очыру, бөтереп йөртү. ◇ **Кружить голову** *разг.* — баш әйләндерү.

**КРУЖИ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. әйләнү; *голова кружится* — башым әйләнә; 2. бөтерелү, бөтерелеп очу; *пыль кружится столбом* — тузан өермә булып бөтерелә. ◇ **Кружиться в вихре удовольствий** — дөньяны онытып рәхәт чигү.

**КРУ'ЖКА** *ж.* — кружка.

**КРУЖКО'ВЕЦ** *м.*, **КРУЖКО'ВКА** *ж.* — кружок члены, түгәрәк члены.

**КРУЖКОВО'Д** *м.* — кружок җитәкчесе, түгәрәк җитәкчесе.

**КРУЖКОВЩИ'НА** *ж. мн.* нет, *неодобр.* — түгәрәкчелек, кружковщина (вак-төяк группаларга бүленеп, коллективтан аерылуга йөз тоту, коллектив интересларын күзәтмәү).

**КРУЖКО'ВЫЙ** — түгәрәк...-ы; *кружковые занятия* — түгәрәк занятиеләре.

**КРУ'ЖНЫЙ**: **кружным путём** — 1. әйләнеч юл белән; 2. *перен.* читләтеп, читтән ишетеп; *узнать что-нибудь кружным путём* — берәр нәрсәне читләтеп белү, читтән ишетеп белү.

**КРУЖО'К** *м.* — 1. түгәрәк әйбер, йомры әйбер; 2. түгәрәк, кружок; *физкультурный кружок* — физкультура түгәрәге.

**КРУМЦИ'РКУЛЬ** *м. спец.* — крумциркуль, кыек циркуль (әйберләрнең юанлыгын һәм эчке күләмен үлчи торган циркуль).

**КРУП I** *м. мед.* — круп, шешенү (бугазның лайлалы ярысы ялкынсыну).

**КРУП II** *м.* — савыр, арт сан, койрык өсте (күбрәк атларда).

**КРУПА'** *ж. мн.* нет — 1. ярма; *гречневая крупа* — карабодай ярмасы; 2. *перен.* ярма кар; *выпала крупа, потом пошли дожди со снегом* (А. Толстой) — ярма кар яуды, аннан соң кар катыш яңгырлар башланды.

**КРУПЕНИ'К** *м. мн.* нет, *кулин.* — йомырканы ботка.

**КРУПИ'НКА** *ж. разг.* — 1. бөртек; *крупинка соли* — тоз бөртеге; 2. *перен.* к. крупица.

**КРУПИ'ЦА** *ж. книж.* — энә очы кадәр, бер бөртек, аз гына; *ни крупицы таланта, истины* — ник энә очы кадәр генә талант, хакыйкать булсын (аз гына да талант, хакыйкать юк).

**КРУПИ'ЧАТЫЙ** — 1. ярмалы; *крупичатый мёд* — ярмалы бал; 2. крупчаткадан пешерелгән; *крупичатый калач* — крупчаткадан пешерелгән калач.

**КРУ'ПКА** *ж.* — 1. *разг.* ярма; 2. *спец.* эре тарттырылган он.

**КРУПНЕ'ТЬ** *несов. разг.* — эреләнү, зураю, эреләнә бару, эреләнә төшү (әйберләр турында).

**КРУ'ПНО** *нареч.* — 1. эре итеп, зур итеп; 2. бик каты, җитди; *крупно повздорить* — бик каты талашып алу; *крупно поговорить* — җитди сөйләшеп алу.

**КРУПНОЗЕРНИ'СТЫЙ** *с.-х.* — эре бөртекле.

**КРУПНОПЛО'ДНЫЙ** *с.-х.* — эре җимешле.

**КРУ'ПНЫЙ** — 1. эре; *крупный песок* — эре ком; *крупный скот* — эре терлек; *крупная промышленность* — эре промышленность; 2. зур; *крупный талант* — зур талант; *крупный писатель* — зур язучы; 3. *разг.* эре гәүдәле, зур гәүдәле; *крупный ребёнок* — эре (зур) гәүдәле бала; 4. *перен.* мөһим, җитди, зур; *крупные события* — мөһим вакыйгалар, зур вакыйгалар; *крупная неприятность* — шактый зур күңелсезлек. ◇ **Между нами произошёл крупный разговор** — безнең арада зур гына әңгәмә булып алды, без каты гына бәрелешеп алдык.

**КРУПОВЕ'ЙКА** *ж. с.-х.* — ярма җилгәргеч.

**КРУПОДЁРКА** *ж. обл.* — к. крупорушка.

**КРУПО'ЗНЫЙ** *мед.* — шешенү...-ы, шешеп...; *крупозные явления* — шешенү күренешләре; *крупозное воспаление лёгких* — үпкәнең шешеп ялкынсынуы.

**КРУПОРУ'ШКА** *ж. с.-х.* — яргыч, ярма яргыч.

**КРУПЧА'ТКА** *ж.* — крупчатка (ак онның иң яхшы сорты).

**КРУПЧА'ТЫЙ** *обл.* — таралучан, ярмасыман.

**КРУПЬЕ'** *м. нескл. спец.* — крупье (буржуаз илләрдә отыш уеннары уйнала торган йортта банк тотучы һәм уенның барышын күзәтеп торучы).

**КРУПЯНО'Й** *с.-х.* — ярма...-ы; *крупяное производство* — ярма производствосы.

**КРУТЕ'НЕК** *просторечь.* — шактый текә.

**КРУТИЗНА'** *мн.* нет, *книж.* — 1. текәлек; 2. текә урын.

**КРУТИ'ТЬ** *несов.* — 1. чирату, кату; *крутить нитки* — җеп кату; 2. бөтерү; *крутить усы* — мыекны бөтерү; 3. әйләндерү; *крутить ручку веялки* — җилгәргечнең тоткасын әйләндерү; 4. чорнау, төрү; *крутить махорку* — махорка чорнау; 5. туздыру, өереп күтәрү; *ветер крутит пыль по дороге* — җил юлдагы тузанны туздыра (өереп күтәрә); 6. бору, йөртү; *она крутит с ним, как хочет* — ул аны теләгән якка бора (теләгәнчә йөртә); 7. (*находиться в любовных отношениях*) *обл.* гыйшык тоту, йөрү; 8. (*кутить*) *обл.* типтерү.

**КРУТИ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. бөтерелү, чорналу; *нитки крутятся* — җеп чорнала; 2. бөтерелеп йөрү, бөтерелеп очып йөрү, әйләнеп йөрү; *листья крутятся в воздухе* — яфраклар һавада бөтерелеп йөриләр; 3. *обл.* гыйшык тоту, йөрү; *она с ним второй год крутится* — ул аның белән икенче ел йөри инде.

**КРУ'ТО** *нареч.* — 1. кисәк, җәһәт, кинәт; *круто повернуть* — кинәт борылу; 2. каты, рәхимсез рәвештә, аяусыз; *круто расправиться* — каты үч алу; 3. каты итеп; *круто сварить яйцо* — йомырканы каты итеп пешерү.

**КРУТОБЕРЕ'ЖНЫЙ** *книж.* — текә ярлы.

**КРУТО'Й** — 1. текә; *крутой берег* — текә яр; 2. кискен, кинәт, каты; *крутой поворот в ходе событий* — вакыйгаларның барышында кискен борылыш; *крутые меры* — кискен чаралар; 3. каты, куе; *крутое тесто* — каты камыр; *крутая каша* — куе ботка; 4. каты пешкән; *крутое яйцо* — каты пешкән йомырка. ◇ **Крутой кипяток** *обл.* — кайнап тора торган су.

**КРУТОРО'ГИЙ** *обл.* — текә мөгезле.

**КРУ'ТОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — 1. текәлек; 2. кискенлек, кинәтлек; 3. шәфкатьсезлек, рәхимсезлек.

**КРУ'ЧА** *ж.* — текә яр.

**КРУЧЁНЫЙ** *спец.* — 1. чиратылган, катылган, бөтерелгән; *кручёные нитки* — чиратылган җеп; 2. *спорт.* бөтерелеп әйләнә торган; *кручёный мяч* — бөтерелеп әйләнә торган туп.

**КРУЧИ'НА** *ж. мн.* нет, *нар.-поэт.* — кайгы, сагыш, хәсрәт.

**КРУЧИ'НИТЬСЯ** *несов. нар.-поэт.* — кайгыру, хәсрәтләнү, кайгыга бирелү, пошыну.

**КРУЧИ'ННЫЙ** *нар.-поэт.* — кайгылы, кайгы-хәсрәтле.

**КРУЧИ'НУШКА** *ж. мн.* нет, *нар.-поэт.* — к. кручина.

**КРУШЕ'НИЕ** *ср.* — 1. һәлакәт; *пароход потерпел крушение* — пароход һәлакәткә очрады; 2. *перен.* җимерелү, юкка чыгу, һәлакәт; *крушение капиталистического строя* — капиталистик стройның җимерелүе.

**КРУШИ'НА** *ж. мн.* нет, *бот.* — эт шомырты.

**КРУШИ'НА СЛАБИТЕЛЬНАЯ** *бот.* — кош куныкас.

**КРУШИ'ТЬ** *несов. книж.* — 1. вату, җимерү, кыру, сындыру; *вихрь крушил леса* — өермә урманда агачларны кыра, сындыра иде; 2. *перен. устар.* тар-мар итү, кыру; *крушить врагов* — дошманнарны кыру; 3. җәфалау, интектерү, йөдәтү; *тоска меня крушит* — мине кайгы җәфалый.

**КРУШИ'ТЬСЯ** *несов. книж. устар. нар.-поэт. обл.* — кайгыру, хәсрәтләнү, кайгыга бирелү.

**КРЫЖО'ВЕННЫЙ** — крыжовник ...-ы; *крыжовенное варенье* — крыжовник вареньесы.

**КРЫЖО'ВНИК** *м. мн.* нет, *бот.* — крыжовник (куагы һәм җимеше).

**КРЫЛА'ТКА** *ж. разг.* — киң ирләр пальтосы.

**КРЫЛА'ТЫЙ** *книж.* — 1. канатлы; *крылатые птицы* — канатлы кошлар; 2. *перен.* ирекле; *крылатые мысли* — ирекле фикерләр. ◇ **Крылатые слова** — канатлы сүзләр, үткен әйтемнәр, афоризмнар.

**КРЫЛА'Ч** *м. спец.* — җиллек, канат (мәсәлән, җилгәргечтә).

**КРЫЛЕ'ЧКО** *ср. разг.* — кечкенә болдыр, өйалды баскычы.

**КРЫЛО'** *ср.* (*мн.* крылья) — 1. канат; *крыло птицы* — кош канаты; *крыло самолёта* — самолёт канаты; 2. өлеш, катлау; *левое крыло английского рабочего движения* — Англия эшчеләре хәрәкәтенең сул өлеше (катлавы). ◇ **Подрезать крылья** *перен.* — канатларын сындыру, канатларын кисү (берәүне үзенең эшчәнлеген, көчләрен киң җәеп җибәрү мөмкинлегеннән мәхрүм итү). **Расправить крылья** *перен.* — канатларны киң җәеп җибәрү (көчләрне киң җәеп җибәрү мәгънәсендә). **Правое крыло дома** — өйнең уң як өлеше.

**КРЫ'ЛЫШКО** *ср. разг.* — кечкенә канат.

**КРЫЛЬЦО'** *ср.* — өйалды баскычы, болдыр.

**КРЫ'НКА** *ж.* — тар муенлы чүлмәк, кринка.

**КРЫ'СА** *ж. зоол.* — 1. күсе; 2. *перен. презр. устар.* күсе (вак чиновник турында); *канцелярская крыса* — канцелярия күсесе.

**КРЫСЁНОК** *м.* (*мн.* крысята) — күсе баласы.

**КРЫСИ'НЫЙ** — күсе...-ы, күсеәр...-ы; *крысиный хвост* — күсе койрыгы.

**КРЫСОЛО'В** *м.* — күсе тотучы (мәсәлән, күсе тота торган эт).

**КРЫСОЛО'ВКА** *ж. разг.* — 1. (*приспособление для ловли крыс*) күсе тәбесе; 2. күсе эте (күсе аулый торган эт).

**КРЫ'ТЫЙ** — 1. ябылган; *крыша, крытая железом* — калай белән ябылган түбә, калай түбә; 2. түбәсе ябылган, ябулы, ябык; *крытый шалаш* — түбәсе ябылган куыш. ◇ **Шито-крыто** — эзе дә юк, һич бәйләнер урын юк.

**КРЫТЬ** *несов.* — 1. ябу, каплау; *крыть избу тёсом* — өй түбәсен такта белән ябу; 2. тышлау; *крыть шубу сукном* — тунны постау белән тышлау; 3. (*в карточной игре*) ябу, сугу; 4. *простореч. вульг.* кирәген бирү, тиргәү, сүгү; *крепко крыть кого-н.* — кемне дә булса бик каты тиргәү. ◇ **Нечем крыть** *простореч. вульг.* — берни дә әйтеп булмый.

**КРЫ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. *устар.* (*прятаться*) яшеренү, качу; 2. *перен. книж.* гыйбарәт, гыйбарәт булу, тору; *в чём кроется причина этого явления?* — бу күренешнең сәбәбе нәрсәдән гыйбарәт? 3. *страд.* ябылу, каплану; тышлану.

**КРЫ'ША** *ж.* — 1. түбә; *железная крыша* — калай түбә; *двускатная крыша* — ике кыеклы түбә; 2. *спец.* өске өлеш; *крыша седла* — иярнең өске өлеше.

**КРЫ'ШКА** *ж.* — капкач, каплавыч. ◇ **Крышка!** *простореч.* — бетте, һәлак булды; *тут ему и крышка* — шунда ул бетте (һәлак булды).

**КРЮК** *м.* — 1. ыргак, элгеч; 2. *с.-х.* (*приспособление на косе*) тырма. ◇ **Сделать крюк или дать крюку** *разг.* — уратып бару, әйләнеч юлдан бару; *пошёл не той дорогой и сделал большой крюк* — туры юлдан китмичә, әллә ни хәтле уратып барганмын.

**КРЮ'ЧИТЬ** *безл. несов. простореч.* — к. корчить 1.

**КРЮ'ЧИТЬСЯ** *несов. простореч.* — к. корчиться.

**КРЮЧКОВА'ТЫЙ** *разг.* — кәкре, ыргаксыман.

**КРЮЧКОТВО'Р** *м. разг. устар. неодобр.* — юри тоткарлык ясаучы, юри эшне чуалтучы (үзенең шәхси максатларын күздә тотып).

**КРЮЧКОТВО'РСТВО** *ср. мн.* нет, *разг. неодобр.* — юри тоткарлык ясау, юри эшне чуалту (үзенең шәхси максатларын күздә тотып).

**КРЮ'ЧНИК** *м. обл. спец.* — крючник, грузчик (авыр әйберләрне ыргак белән эләктереп ташучы).

**КРЮ'ЧНИЧАТЬ** *несов. обл.* — крючник булып эшләү, грузчик булып эшләү.

**КРЮЧО'К** *м.* — 1. кечкенә ыргак, эләктергеч; (*дверной*) келә; (*для рыбной ловли*) кармак; (*у одежды*) каптырма; 2. *разг. устар. неодобр.* к. крючкотвор.

**КРЮШО'Н** *м.* — крюшон (җимештән ясалган аракының ром яки коньяк белән кушылмасы).

**КРЯ'ДУ** *нареч. простореч.* — тоташтан, беррәттән.

**КРЯЖ** *м.* — 1. тәбәнәк таулар тезмәсе; 2. кискә, түмәр.

**КРЯ'ЖИСТЫЙ** *простореч.* — 1. (*о дереве*) нык, таза, юан; 2. *перен.* (*о человеке*) нык, таза, көчле.

**КРЯ'КАТЬ** *несов.* — 1. (*об утке*) бакылдау; 2. *разг. фам.* (*о человеке*) тамак кыру.

**КРЯ'КВА** *ж. зоол.* — кыр үрдәге.

**КРЯ'КНУТЬ** *сов. однокр.* — 1. бакылдап кую; 2. тамак кырып кую.

**КРЯХТЕ'ТЬ** *несов. разг.* — 1. ахылдау, ухылдау, ыңгырашу; 2. *перен.* (*жаловаться*) зарлану, сукрану.

**КРЯХТУ'Н** *м.*, **КРЯХТУ'НЬЯ** *ж. простореч.* — 1. ыңгырашучы; 2. зарланучы, сукранучы.

**КСЁНДЗ** *м. церк.*— ксёндз (полякларда католик руханн).

**КСЕРОФО'РМ** *м. мн.* нет, *мед.*— ксероформ (ярага сибү өчен кулланыла торган саргылт порошок, висмут һәм бром кушылмасы).

**КСИЛОГРА'ФИЯ** *ж.*— ксилография (1. агачка чокып рәсемнәр төшерү; 2. шундый рәсемнәр).

**КСИЛОФО'Н** *м. муз.*— ксилофон (ящикка беркетелгән агач пластинкалардан тора торган һәм шул пластинкаларга агач таякчыклар белән сугып уйнала торган музыка коралы).

**КСТА'ТИ** *нареч.*—1. урынлы, бик урынлы; вакытлы, бик вакытлы; *твой ответ пришёлся как нельзя более кстати* — синең җавабың бик урынлы булып чыкты; 2. бер уңайдан, уңае килгәндә, туры килгәндә; *если будете в бухгалтерии, кстати наведите справку о моём деле* — әгәр бухгалтериядә була калсагыз, бер уңайдан минем эшем турында да белешегез әле; 3. *в знач. ввод. сл.* сүз җаенда, сүз уңаенда (әйткәндә); *кстати сказать, когда вы виделись с ним в последний раз?* — сүз уңаенда әйткәндә, сез аның белән соңгы тапкыр кайчан күрештегез? *я, кстати, в то время увлекался спортом* — сүз җаенда әйткәндә, мин ул вакытта спорт белән мавыга идем.

**КТО** *местоим.*—1. (*вопросительное*) кем, кемнәр; *кто вам сказал об этом?* —сезгә бу турыда кем әйтте? 2. (*разделительное*) берәү, берәүләр; *кто ждал денег, кто письма, кто газет* — берәүләр акча, берәүләр хат, берәүләр газета көтә иде; 3. (*неопределённое*) *разг.* берәр кеше, кем дә булса; *если кто придёт, скажи, что я на работе* — әгәр берәр кеше килсә, мине эштә диген. ◇ **Кто бы ни** — кем генә булмасын, кем генә булса да.

**КТО'-ЛИБО** — к. кто-нибудь.

**КТО'-НИБУДЬ** — кем булса да, кем дә булса, берәрсе; *спроси кого-нибудь из служащих* — хезмәткәрләрнең берәрсеннән сора.

**КТО'-ТО** — кемдер, берәү, бер кеше; *кто-то ждёт тебя* — сине кемдер көтеп тора.

**КУАФЁР** *м. устар.*— парикмахер.

**КУБ I** *м.*— куб (1. *мат.* һәр ягы квадрат булган алты яклы фигура; 2. куб метр, бер кубик метр зурлыгындагы күләм үлчәве; 3. су кайнату өчен капкачлы савыт; 4. *мат.* берәр санның өченче дәрәҗәсе).

**КУБ II** *м. бот.*— куб (зәңгәр буяу алына торган үсемлек).

**КУБА'НКА** *ж. обл.*— кубанка (1. бодайның бер сорты; 2. мех кырпулы, яссы күн түбәле бүрек).

**КУ'БАРЕМ** *нареч. разг.*— мәтәлеп, мәтәлчекләп.

**КУ'БАРЬ** *м.* — бөтерчек (балалар уенчыгы).

**КУБАТУ'РА** *ж. мн.* нет, *спец.*— кубатура (өй, бүлмә кебекләрнең кубик күләме).

**КУ'БИК** *м.*—1. кубик (берәр сыекчаның кубик сантиметры); *два кубика спирта* — ике кубик спирт (ике кубик сантиметр спирт); 2. шакмак уены; *играть в кубики* — шакмак уены уйнау; 3. шакмак (уенчык шакмакларның берсе).

**КУБИ'ЧЕСКИЙ** — куб формасындагы; кубик; *кубическая форма* — кубик форма; *кубический метр* — кубик метр.

**КУБОВИ'ДНЫЙ** *книж.*—кубсыман, кубка охшаган, куб формасындагы.

**КУ'БОВЫЙ** — җете зәңгәр, куе зәңгәр, зәп-зәңгәр.

**КУ'БОК** *м.*— кубок (1. зур бокал формасында металл савыт; 2. *спорт.* спорт ярышларында җиңүчегә бирелә торган бүләк, приз).

**КУБОМЕ'ТР** *м.*— кубометр, кубик метр.

**КУ'БРИК** *м. мор.*— кубрик (судноның аскы палубасы).

**КУБЫ'ШКА** *ж.*—1. *простореч. шутл.* акча чүлмәге; 2. *бот.* сары төнбоек; 3. *перен. просторец.* (*о толстой, пухлой женщине, девушке, ребёнке*) ит бүкәне.

**КУВА'ЛДА** *ж.*—1. *тех.* зур, авыр чүкеч; 2. *перен. просторец. вульг. неодобр.* (*о грузной, неуклюжей женщине*) алпавыт бисе.

**КУВШИ'Н** *м.* — чүлмәк, кувшин.

**КУВШИ'НКА** *ж. бот.* — ак төнбоек.

**КУВШИ'ННЫЙ** — чүлмәк ...-ы; *кувшинная ручка* — чүлмәк тоткасы.

**КУВШИ'НЧИК** *м. обл.* — к. кувшинка.

**КУВЫ'РК** *в знач. сказ. просторец.*— мәтәлеп китте.

**КУВЫ'РКА'ТЬ** *несов. просторец.*— астын өскә әйләндерү.

**КУВЫ'РКА'ТЬСЯ** *несов. разг.*—1. мәтәлү, мәтәлчек ату; 2. *страд.* асты өскә әйләндерелү.

**КУВЫРКНУ'ТЬ** *сов. однокр.*— астын өскә әйләндереп кую.

**КУВЫРКНУ'ТЬСЯ** *сов. однокр.*— мәтәлеп төшеп китү, мәтәлеп егылып китү.

**КУВЫРКОЛЕ'ГИЯ** *ж. просторец. шутл.*—1. мәтәлеп егылу; 2. *ирон.* тәртипсезлек, башбаштаклык, өзлексез үзгәрешләр (берәр учреждениенең составында).

**КУВЫРКО'М** *нареч. разг. фам.*— мәтәлеп, мәтәлчекләп.

**КУВЫРНУ'ТЬ, КУВЫРНУ'ТЬСЯ** — к. кувыркнуть, кувыркнуться.

**КУГУА'Р** *м. зоол.*— кугуар, зур кыргый мәче (Америкада).

**КУДА'** *нареч.*—1. (*вопросит.*) кая? кай төшкә? *куда вы едете?* — сез кая барасыз? 2. (*вопросит.*) нәрсәгә? *куда вам столько денег?* — нәрсәгә сезгә шулкадәр акча? 3. (*с восклиц. интонацией*) кая инде ул; *куда тебе сладить!* — кая инде ул сиңа аны җиңү! 4. (*гораздо, несравненно*) бик, күп, бик күп, чагыштыргысыз; *куда дешевле* — күп арзан; *работа идёт куда дружней* — эш бик бердәм бара; 5. (*неопредел.*) берәр җиргә, кая да булса; *если куда пойдёте, скажите мне* — берәр җиргә (кая да булса) барсагыз, миңа әйтегез. ◇ **Хоть куда** *просторец.*—менә дигән, карап туйгысыз (яхшы); *парень хоть куда* —

егете менә дигән. Куда как *разг. устар.*— бик, үтә; *куда как чуден создан мир* — дөнья бик матур итеп төзелгән. Куда ни шло — булмаса булган икән.

**КУДА'-ЛИБО** *нареч. книж.*— кая булса да, кая да булса, берәр җиргә.

**КУДА'-НИБУДЬ** *нареч.*— кая да булса.

**КУДА'-ТО** *нареч.*— каядыр.

**КУДА'ХТАТЬ** *несов.*— кытаклау.

**КУДЕ'ЛЬ** *ж. спец.*— тәрәшле сүс.

**КУДЕРЬКИ'** *ед.* нет, *простореч.*— к. кудри.

**КУДЕ'СИТЬ** *несов. обл. устар.*— шаяру, шуклану, кылану.

**КУДЕ'СНИК** *м. книж. поэт. устар.*— сихерче.

**КУДЛА'СТЫЙ, КУДЛА'ТЫЙ** *простореч.*— йонлач, чәчби, тузган чәчле, пумала баш.

**КУДРЕВА'ТЫЙ** *простореч.*— бераз көдрә (бөдрә).

**КУ'ДРИ** *ед.* нет — бөдрә чәч, көдрә чәч.

**КУДРЯ'ВИТЬСЯ** *несов. разг.*— бөдрәләнү, көдрәләнү.

**КУДРЯ'ВЫЙ** —1. көдрә, бөдрә; *кудрявые волосы* — көдрә чәч; 2. көдрә чәчле, бөдрә чәчле; *кудрявый мальчик* — көдрә (бөдрә) чәчле малай; 3. *(о литературном стиле) перен.* кирәгеннән артык бизәкле, кирәгеннән артык тасвирлы; *кудрявый стиль*— кирәгеннән артык бизәкле стиль.

**КУДР'ЯШ** *м. обл. нар.-поэт.* — көдрә (бөдрә) чәчле егет, малай.

**КУДРЯ'ШКИ** *ед.* нет, *разг. фам.*— к. кудри.

**КУДЫ'** *нареч. обл. простореч.*— к. куда.

**КУЗЕ'Н** *м.* — тудыка, туганнан туган (абый яки эне).

**КУЗИ'НА** *ж.*— тудыка, туганнан туган (апа яки сеңел).

**КУЗНЕ'Ц** *м.*— тимерче.

**КУЗНЕ'ЧИК** *м. зоол.*—1. *(насекомое)* чикерткә, сикерткә; 2. *обл. (синица)* песнәк.

**КУЗНЕ'ЧИТЬ** *несов. обл.*— тимерчелек эше белән шөгыльләнү.

**КУЗНЕ'ЧНЫЙ** — тимерче...-ы; тимерчеләр ...-ы; *кузнечный молот* — тимерче чүкече; *кузнечный цех* — тимерчеләр цехы.

**КУ'ЗНИЦА** *ж.*—1. тимерче алачыгы; 2. *перен.* чыныктыру урыны; *пионерский лагерь — кузница труда* — пионерлар лагере—хезмәткә чыныктыру урыны.

**КУ'ЗОВ** *м.*—1. *(из лыка)* тубал, *(из бересты)* козау; 2. *(у тарантаса)* читән, күрек; 3. *(у автомобиля)* кузов.

**КУ'ЗЬКА** *м. зоол. с.-х.*— иген коңгызы.

**КУ'ЗЬКИНА МАТЬ: показать кузькину мать** *простореч. вульг.*— кирәген бирү, күрмәгәнен күрсәтү; *он тебе покажет кузькину мать!* — ул синең кирәгеңне бирер!

**КУКАРЕ'КАТЬ** *несов. обл.* — кычкыру (әтәч кычкыруы), кикрикүк дип кычкыру.

**КУКАРЕ'КНУТЬ** *сов. однокр. обл.*— кычкырып җибәрү (әтәч).

**КУКАРЕКУ'** *звукоподраж.* — кикрикүк.

**КУ'КИШ** *м. разд.*— кукиш, кәҗә тоягы. ◇ Кукиш с маслом *простореч.*— бернәрсә дә чыкмады.

**КУ'КЛА** *ж.*—1. курчак; 2. *перен. разг. неодобр.*— рухсыз, сүлпән хатын.

**КУКОВА'ТЬ** *несов.* — кычкыру (күке), „кәкүк" дип кычкыру.

**КУ'КОЛКА** *ж.* — курчак (1. уенчык; 2. *разг. фам.* матур киенгән кыз бала; 3. күбәләкнең йомгактагы чагы).

**КУ'КОЛЬ** I *м. мн.* нет, *бот.*— бакра.

**КУ'КОЛЬ** II *м. церк.*— монах бүреге.

**КУ'КОЛЬНЫЙ** — курчак...-ы; *кукольный магазин* — курчак магазины; *кукольный театр* — курчак театры. ◇ Кукольная комедия *перен. разг. презрит.*— курчак кәмите (риялы, ясалма тантана). Кукольный домик *книж. устар.*— тиз таркалучан, тотрыксыз семья.

**КУ'КСИТЬСЯ** *несов. разг. фам.*— чырай сыту, каш җыеру, кәефсезләнү.

**КУКУ'** *звукоподраж.* — кәккүк (күке тавышы).

**КУКУРЕ'КАТЬ, КУКУРЕ'КНУТЬ, КУКУРЕ'КУ** — к. кукарекать и т. д.

**КУКУРУ'ЗА** *ж. мн.* нет, *бот.*— кукуруз.

**КУКУРУ'ЗНЫЙ** —1. кукуруз ...-ы; *кукурузная мука* — кукуруз оны; 2. кукуруз ...-ы, кукуруздан пешерелгән; *кукурузный хлеб* — кукурузадан пешерелгән икмәк.

**КУКУ'ШЕЧНЫЙ** — күке ...-ы; *кукушечное яичко* — күке йомыркасы.

**КУКУ'ШКА** *ж.*— күке, кәккүк.

**КУКУ'ШКИН ЛЁН** *м. мн.* нет, *бот.*— күке житене (мүк).

**КУКУ'ШКИНЫ СЛЁЗЫ** *бот.*— күке яше (үсемлек).

**КУЛА'К** I *м.* — 1.*(кисть руки с сжатыми пальцами)* йодрык; 2. *(деталь машины)* йодрыкча; *шестерня в шесть кулаков* — алты йодрыкчалы шестерня.

**КУЛА'К** II *м.*— кулак, байгура (батракларны, ярлыларны эксплуатацияләүче бай крестьян).

**КУЛА'ЦКИЙ** — кулак ...; кулак ...-ы; кулаклар ...-ы; *кулацкие элементы* — кулак элементлар; *кулацкое восстание* — кулаклар баш күтәрүе.

**КУЛА'ЧЕСТВО** *ср. мн.* нет, *собир.*— кулаклар.

**КУЛА'ЧКА** *ж.*— кулак хатын-кызы.

**КУЛА'ЧКИ: итти на кулачки** — йодрыкка йодрык килеп сугышу, йодрык белән сугышу.

**КУЛАЧКО'ВЫЙ** *тех.*— йодрыкчалы; *кулачковый вал* — йодрыкчалы вал.

**КУЛА'ЧНЫЙ** —1. йодрык ...-ы; *кулачный бой* — йодрык сугышы; 2. йодрыкча ...-ы; *кулачная шайба* — йодрыкча шайбасы. ◇ Кулачное право *публиц.* — йодрык хокукы (җәмгыятьтә көчлеләр хакимлек итүе һәм шәхси хокукның бернәрсә белән дә якланмаган булуы).

**КУЛАЧЬЁ** *ср. мн.* нет, *собир. простореч. презрит.*— кулаклар, кулаклар өере.

**КУЛЕБЯ'КА** *ж.*— бәлеш, озынча бөккән.

**КУЛЁК** *м.*— 1. кечкенә кап; 2. кәгазь

пакет. ◇ **Из кулька в рогожку** — каш төзәтәм дип күз чыгару.

**КУЛЕТКА'ЦКИЙ** — кап сугу ...-ы; *кулеткацкий промысел* — кап сугу һөнәре.

**КУЛЕ'Ш** *м. обл.*— өйрә, сыек ботка.

**КУ'ЛИ** *м. нескл.*— кули, кара эшче, йөк ташучы (Һиндстанда, Япониядә, Индонезиядә, Кытайда).

**КУЛИ'К** *м. зоол.*— шөлди, кулик (кош).

**КУЛИ'КАТЬ** *несов. обл.*— эчүгә бирелү, эчеп йөрү.

**КУЛИНА'Р** *м.*— кулинар, аш остасы, пешекче.

**КУЛИНАРИ'Я** *ж. мн.* нет— кулинария (1. аш хәзерләү осталыгы; 2. ашамлыклар, ашамлык әйберләре).

**КУЛИНА'РНЫЙ** — кулинария ...-ы; *кулинарные курсы* — кулинария курслары.

**КУЛИ'СА** *ж.*—1. *театр.* ян декорация; 2. *перен. только мн.* артистлар средасы; 3. *тех.* кулиса (машинаның йөрешен үзгәртү өчен хезмәт итә торган рычаг яки рычаглар системасы). ◇ **За кулисы** *театр.*— сәхнә артына. **За кулисами** — 1. сәхнә артында; 2. *перен.* яшертен, яшерен рәвештә.

**КУЛИ'Ч** *м.*— кулич (пасха күмәче).

**КУЛИ'ЧКИ** *ед.* нет, *просторечь. шутл.*: **к чорту на кулички** — бик еракка, җәһәннәм артына; **у чорта на куличках** — бик еракта, җәһәннәм артында.

**КУЛО'Н** I *м.* кулон (чылбырга тагылган яки муенсага тезелгән кыйммәтле асылташ).

**КУЛО'Н** II *м. физ.*— кулон (электр микъдарының практик берәмлеге).

**КУЛУА'Р** *м.* — кулуар (1. парламентта, театрда, съездларда утырышлар залы тышындагы бүлмәләр, коридорлар; 2. *перен.* парламент средасы).

**КУЛУА'РНЫЙ** — кулуардагы, кулуарда эшләнгән; *кулуарные встречи* — кулуардагы очрашулар.

**КУЛЬ** *м.*— 1. кап; 2. *обл.* сугылган көлтә, салам учмасы.

**КУЛЬМИНАЦИО'ННЫЙ** *книж.*— кульминацион, иң югары, иң югарыгы; *кульминационная точка* — кульминацион нокта, иң югары нокта.

**КУЛЬМИНА'ЦИЯ** *ж. книж.*— кульминация (1. *астр.* күктәге яктырткычның меридиан аша үтүе; 2. *перен.* әдәби әсәрдәге вакыйгалар үсешендә иң киеренке момент).

**КУЛЬМИНИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. книж.*— 1. *астр.* меридиан аша үтү; 2. *перен.* үсештә иң югары ноктага ирешү.

**КУЛЬТ** *м. книж.*— 1. гыйбадәт, табыну; 2. *перен.* культ, артык олылау, артык зур хөрмәт, табыну. ◇ **Служители культа** — руханилар (поплар, муллалар, мәзиннәр).

**КУЛЬТИВА'ТОР** *м. с.-х.* — культиватор (сөрелгән җирне йомшарту коралы).

**КУЛЬТИВА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *спец.*— к. культивировать.

**КУЛЬТИВИ'РОВАТЬ** *несов. книж.*— 1. үстерү, иген үстерү; *на юге Советского Союза культивируют сою* — Советлар Союзының көньягында соя үстерәләр; 2. *перен.* җәелдерү, тарату, гадәткә кертү; *культивировать рациональные способы работы* — эшнең рациональ ысулларын җәелдерү; 3. культиватор белән эшкәртү.

**КУЛЬТИВИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд. книж.*—1. үстерелү, иген үстерелү; 2. җәелдерелү, таратылу, гадәткә кертелү.

**КУЛЬТПОХО'Д** *м.*— культпоход (1. кыска вакыт эчендә халык арасындагы укый-яза белмәүчелек һәм наданлыкны бетерү өчен үткәрелә торган массовый чаралар; 2. театрга, музейга, кинога һ. б. коллектив белән бару).

**КУЛЬТУ'РА** *ж. книж.*—1. культура (а. кешеләрнең табигатьне буйсындыруда, техникада, аң-белемдә, иҗтимагый төзелештә ирешкәннәренең барлыгы; б. иген, үстерелгән үсемлек; *сельскохозяйственные культуры* — авыл хуҗалыгы культуралары); 2. *с.-х.* иген үстерү; *культура льна*— җитен иген үстерү; 3. үрчетү; *культура шёлкопряда* — ефәк кортын үрчетү; *культура бактерий* — бактерияләр үрчетү (лабораторияләрдә); 4. *перен.* камилләштерү, бик нык яхшырту; *актёру требуется культура голоса, движений* — актёрга тавышын, хәрәкәтен камилләштерергә кирәк.

**КУЛЬТУ'РНО** *нареч.*— культуралы, әдәпле, инсафлы; *культурно вести себя* — үзеңне әдәпле тоту.

**КУЛЬТУ'РНО-БЫТОВО'Й**— культура-көнкүреш ...-ы; *культурно-бытовые вопросы* — культура-көнкүреш мәсьәләләре.

**КУЛЬТУ'РНО- ВОСПИТА'ТЕЛЬНЫЙ** — культура -тәрбия ...-ы; *культурно-воспитательные работы*—культура-тәрбия эшләре.

**КУЛЬТУ'РНО-МА'ССОВЫЙ** — культура-масса ...-ы; *культурно-массовые работы* — культура-масса эшләре.

**КУЛЬТУ'РНО-ПРОСВЕТИ'ТЕЛЬНЫЙ** — культура-агарту ...-ы; аң-белем тарату ...-ы; *культурно-просветительные мероприятия* — аң-белем тарату чаралары.

**КУЛЬТУ'РНОСТЬ** *ж. мн.* нет — культуралылык, үсеш дәрәҗәсе; югары культуралылык.

**КУЛЬТУ'РНЫЙ** — 1. культура ...-ы, культура өлкәсендәге; *культурный уровень* — культура дәрәҗәсе; 2. культуралы, белемле; *культурный человек* — культуралы кеше; 3. аң-белем тарату ...-ы; *культурный сектор* — аң-белем тарату секторы; 4. иген үстерелә торган; *культурные растения* — иген үстерелә торган үсемлекләр; 5. игүгә яраклы; *культурный участок земли* — игүгә яраклы җир участогы. ◇ **Культурный слой земли** — җирнең культуралы катлавы (җирнең күмер, көл, хайван сөякләре, савыт-саба ватыклары табыла торган катлавы; шул нәрсәләрне өйрәнү нигезендә бу урында яшәгән кешеләрнең тарихын ачалар).

**КУЛЬТУРТРЕ'ГЕР** *м. публиц.*— культуртрегер (культуралаштырам дигән булып, артта калган халыкларны коллыкка төшерүче империалист-колонизатор).

**КУЛЬТУРТРЕ'ГЕРСКИЙ** *публиц.*— культуртрегер ...-ы; культуртрегерлар ...-ы; культуртрегерлык ...-ы; *культуртрегерская политика* — культуртрегерлар политикасы.

**КУЛЬТУРТРЕ'ГЕРСТВО** *ср. мн.* нет, *публиц.*— культуртрегерлык.

**КУЛЬТЯ', КУЛЬТЯ'ПКА** *ж. разг. обл. мед.*— гарип кул калдыгы, гарип аяк калдыгы (гарипләнү сәбәпле киселеп ташланган кул-аякның гәүдәдә калган өлеше).

**КУМ** (*мн.* кумовья) *м. разг. устар.*— кум, кода (христианнарда баланы чукындырган ир кеше).

**КУМА'** *ж.*— 1. кума, кодагый (христианнарда баланы чукындырган хатын кеше); 2. кодагый (әкиятләрдә төлке кушаматы).

**КУМАНЁК** *м. ласк. обл.*— к. кум.

**КУМАНИ'КА** *ж. мн.* нет, *обл. бот.*— күк бөрлегән.

**КУМА'Ч** *м. мн.* нет — комач, бурлат (җете кызыл төстәге материя).

**КУМАЧЁВЫЙ** *обл.*, **КУМА'ЧНЫЙ** — комач ...; *кумачевая рубаха* — комач күлмәк.

**КУМЕ'КАТЬ** *несов. обл.*— уйлану, фикер йөртү.

**КУМИ'Р** *м. книж. поэт.*— кумир (1. мәҗүсиләрдә алла сыны, санам, пот; 2. сокландыргыч, үзәк өзгеч, табыну дәрәҗәсендә яратылучы).

**КУМИ'РНЯ** *ж.*— потханә (мәҗүсиләр гыйбадәтханәсе).

**КУМИ'ТЬСЯ** *несов. обл.*— 1. кодалашу; 2. *перен.* дуслашу.

**КУМОВСКО'Й** *разг. неодобр.*— кода-кодагыйлык ...-ы, яклашу ...-ы; *кумовские отношения* —кода-кодагыйлык мөнәсәбәтләре, яклашу мөнәсәбәтләре.

**КУМОВСТВО'** *ср. мн.* нет — 1. кодалык мөнәсәбәтләре; 2. *перен. неодобр.* яклашу.

**КУМУЛЯ'ЦИЯ** *ж. мед.*— кумуляция (озак вакытлар куллану нәтиҗәсендә дару матдәләренең яки агуларның организмда артык күбәеп китүе).

**КУ'МУШКА** *ж.*— 1. кодагый; 2. *разг. неодобр.* гайбәтче хатын.

**КУМЫ'КИ** *мн.* (*ед.* кумык)—комыклар, комык халкы (Кавказда яшәүче төрки халыкларның берсе).

**КУМЫ'С** *м. мн.* нет — кымыз.

**КУМЫ'СНИК** *м.*— кымыз эчеп дәвалanучы.

**КУМЫСОЛЕЧЕ'БНИЦА** *ж. мед.*— кымыз санаторие.

**КУМЫСОЛЕЧЕ'БНЫЙ** *мед.*— кымыз белән дәвалау ...-ы; *кумысолечебное заведение* — кымыз белән дәвалау заведениесе.

**КУМЫСОЛЕЧЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *мед.*— кымыз белән дәвалау.

**КУМЫ'ЦКИЙ** — комык ...-ы; *кумыцкий язык* — комык теле.

**КУМЫ'ЧКА** *ж.*— комык хатын-кызы.

**КУН** *м. мн.* нет, *истор.*— кун (элекке төрки һәм Кавказ халыкларында кеше үтергән өчен йолым түләп котылу).

**КУНА'К** *м.*— кунак (Кавказ тау халыкларында дус кеше, якын иптәш).

**КУНА'ЧЕСТВО** *ср. мн.* нет — кунакка йөрешү, дус булышу.

**КУНЖУ'Т** *м. бот.*— кунжут (эссе илләрдә үсә торган майлы үсемлек).

**КУНЖУ'ТНЫЙ** *бот.*— кунжут ...-ы; *кунжутное масло* — кунжут мае.

**КУ'НИЙ** — сусар...-ы; *куний мех* — сусар мехы.

**КУНИ'ЦА** *ж. зоол.*— 1. сусар; 2. сусар мехы.

**КУНКТА'ТОР** *м.*— мыштым кеше, акрын кыймылдаучы кеше.

**КУНСТКА'МЕРА** *ж. истор.*— кунсткамера (1. сирәк очрый торган әйберләр җыелмасы; шундый әйберләр саклау урыны, музей; 2. *перен. разг.* искелек тарафдарлары, иске тормышны яклаучылар җыелган урын).

**КУНТУ'Ш** *м.*— кунтуш (элекке поляклар һәм украинлылар чикмәне).

**КУ'НШТЮК** *м. разг. фам.*— фокус, житез алым, әкәмәт кыланыш.

**КУ'ПА** *ж. книж. устар.*— өем, төркем; *купы деревьев* — агач төркемнәре.

**КУПА'ЛЕНКА** *ж. разг.*— к. купальня.

**КУПА'ЛЬНЫЙ** — коену...-ы; *купальный сезон* — коену сезоны.

**КУПА'ЛЬНЯ** *ж.*— купальня (су коену өчен ясалган махсус корылма).

**КУПА'ЛЬЩИК** *м.*, **КУПА'ЛЬЩИЦА** *ж.*— су коенучы; су коенырга яратучы.

**КУПА'НЬЕ** *ср.*— 1. коену; коендыру; 2. коену урыны.

**КУПА'ТЬ** *несов.*— коендыру.

**КУПА'ТЬСЯ** *несов.*— коену, су коену, су керү. ◇ **Купаться в золоте** *разг. перен.*— алтынга чуму, гадәттән тыш бай булу.

**КУПЕ'** *ср. нескл. ж.-д.*— купе, вагон бүлмәсе.

**КУПЕ'ЛЬ** *ж. церк.*— купель (баланы чукындыру йоласын үтәгәндә аны коендыра торган ләгән).

**КУПЁНА** *ж. бот.*— бүре җиләге.

**КУПЁНА ЛЕКА'РСТВЕННАЯ** *ж. бот.*— сөләйман мөһере.

**КУПЕ'Ц** *м.*— сәүдәгәр, купец.

**КУПЕ'ЦКИЙ** *простореч.*— 1. к. купеческий; 2. *пренебр.* сәүдәгәрләр...-ы; сәүдәгәрләргә хас; *купецкая манера* — сәүдәгәрләр кыланышы.

**КУПЕ'ЧЕСКИЙ** — сәүдәгәрләр...-ы; сәүдәгәрлек...-ы; *купеческое сословие* — сәүдәгәрләр сословиесе.

**КУПЕ'ЧЕСТВО** *ср. мн.* нет, *собир. дорев.*— 1. сәүдәгәрләр, купецлар; 2. сәүдәгәрләр сословиесе, купецлар сословиесе.

**КУПИДО'Н** *м.*— 1. *поэт. устар.* мәхәббәт алласы (римлылар мифологиясендә); 2. *фам.* бик чибәр егет.

**КУПИ'ТЬ** *сов.*— 1. (*приобрести на деньги*) сатып алу; 2. взятка белән үз ягына аудару, сатып алу; 3. *карт. арго* алу; *купить туза* — туз алу.

**КУПЛЕ'Т** *м.*— куплет (җыр, шигырь строфасы).

**КУПЛЕТИ'СТ** *м.*, **КУПЛЕТИ'СТКА** *ж. театр.*— куплетчы, такмазачы (мәзәк, сатирик җырлар башкаручы эстрада артисты).

**КУПЛЕ'ТЫ** *мн.*— такмак, такмаза (көндәлек вакыйгаларга багышланган шаян җырлар).

**КУ'ПЛЯ** *ж. мн.* нет — сатып алу.
**КУ'ПНО** *нареч. книж. устар.* — бергә, бергәләп, берлектә.
**КУ'ПОЛ** *м.* (*мн.* купола́) — гөмбәз.
**КУПОЛООБРА'ЗНЫЙ** *книж.* — гөмбәз-сыман.
**КУ'ПОЛЬНЫЙ** *архит.* — гөмбәз...-ы; *купольное перекрытие* — гөмбәз тәрәге.
**КУПО'Н** *м.* — купон (1. кыйммәтле кәгазьләрнең процентын алу өчен киселә торган талон; 2. *спец.* театр ложасына бер урынлык билет).
**КУПО'ННЫЙ** — купон...-ы; *купонный налог* — купон налогы.
**КУПОРО'С** *м. мн.* нет, *хим.* — купорос. ◇ **Медный купорос** — күкташ. **Железный купорос** — яшел зәңгәр.
**КУПОРО'СНЫЙ** *хим.* — купорос...-ы; *купоросное масло* — купорос мае.
**КУПРИ'Т** *м. геол.* — куприт, бакыр рудасы.
**КУПЦО'ВСКИЙ** *разг.* — купецларча..., купецларга хас, сәүдәгәрләрчә..., сәүдәгәрләргә хас; *купцовский способ* — сәүдәгәрләргә хас алым.
**КУ'ПЧИЙ** *офиц. дореvол.*: **купчая крепость** — купчий кәгазе, нялек кәгазе (күчми торган милек сатып алуны раслап нотариус тарафыннан бирелгән документ).
**КУ'ПЧИК** *м. разг. презрит.* — яшь сәүдәгәр.
**КУПЧИ'НА** *м. разг. уничижит.* — юан корсаклы сәүдәгәр.
**КУПЧИ'ХА** *ж.* — 1. хатын-кыз сәүдәгәр; 2. сәүдәгәр хатыны.
**КУПЮ'РА** *ж.* — купюра (1. әсәрне, текстны кыскарту; 2. берәр заёмның яки башка бер кыйммәтле кәгазьнең аерым бер облигациясе, аерым бер кисәге).
**КУР** *м. старин.* — әтәч (хәзер ул мәгънәдә кулланылмый, түбәндәге әйтемдә генә кулланыла: **как кур во щи попал** — көтелмәгән бер бәлагә, күңелсезлеккә очрады (м, н). юлыкты (м, н).
**КУ'РА** *ж. обл.* — тавык.
**КУРАГА'** *ж. мн.* нет — күрәгә (төше алып киптерелгән өрек).
**КУРА'Ж** *м. разг.* — ясалма батырлык, кыюлык, әтәчләнү.
**КУРА'ЖИТЬСЯ** *несов. простореч.* — тәрбиясезләнү, оятсызлану, бәйләнчекләнү, үзен оятсыз тоту, тупас кылану, борын күтәрү, кешене мыскыл итү.
**КУРА'НТ** *м. спец.* — төйгеч, кисап (буяу төю өчен).
**КУРА'НТЫ** *ед.* нет — курантлар (башняга куела торган музыкалы сәгать).
**КУРА'ТОР** *м.* — куратор (1. *устар.* опекун, тәрбия итүче; 2. *мед.* клиникада авыруларны күзәтеп торучы студент).
**КУРБЕ'Т** *м.* — 1. *спорт.* курбет (атның алгы аякларын бөкләп сикерүе; акробатикада — сикерүнең бер төре); 2. *перен. фам. неодобр.* кыланыш, кирелек.
**КУ'РВА** *ж. вульг. бран.* — фахишә.
**КУРГА'Н** *м.* — 1. курган (борынгы каберлек өстендә өелеп, калкып тора торган биеклек); 2. тауҹык, курган.
**КУРГА'ННЫЙ** — курган...-ы, курганда ...-а торган; *курганная керамика* — курганда табыла торган керамика. ◇ **Курганная баба** — к. каменная баба.
**КУРГУ'ЗЫЙ** *простореч.* — 1. (*об одежде*) кыска, тар; 2. (*о животных*) кыска койрыклы, көтек койрыклы.
**КУ'РДСКИЙ** — көрд...-ы; *курдский язык* — көрд теле.
**КУ'РДЫ** *мн.* (*ед.* курд) — көрдләр, көрд халкы (Иранда, Төркиядә, Гыйракта, өлешчә Азербайҗанда, Әрмәнстанда һәм Төркмәнстанда яши торган халык).
**КУРДЮ'К** *м.* — курдюк, куй койрыгы.
**КУРДЮ'ЧНЫЙ** — 1. койрык...-ы, курдюк...-ы; *курдючное сало* — койрык мае, курдюк мае; 2. курдюклы; *курдючная овца* — курдюклы сарык.
**КУРДЯ'НКА** *ж.* — көрд хатын-кызы.
**КУ'РЕВО** *ср. мн.* нет, *простореч.* — 1. тәмәке; 2. төтәсләү әйбере, ыслау әйбере; 3. *обл.* төтен.
**КУРЕ'НИЕ** *ср.* — 1. к. курить; 2. *книж.* хуш ис чыгару өчен яндырыла торган матдә.
**КУРЁНОК** *м. обл.* — чебеш.
**КУ'РЕНЬ** *м.* — 1. *обл.* саламнан ясалган куыш, шалаш; 2. *истор.* курень (Запорожье казакларының хәрби станы бүлеге); 3. *обл.* өй.
**КУРЗА'Л** *м.* — курзал (курортларда гомуми зал).
**КУ'РИВАТЬ** *многокр. несов.* — тәмәке тарткалау.
**КУ'РИЙ** *обл.* — к. куриный.
**КУРИ'ЛКА** *м.* и *ж. простореч.* — 1. *ж.* тәмәке тарту бүлмәсе; 2. *м.* и *ж. шутл.* тәмәкече.
**КУРИ'ЛЬНЯ** *ж.* — наркотиклар тарту урыны (буржуаз илләрдә әфьюн, нәшә һ. б. тарту урыны).
**КУРИ'ЛЬЩИК** *м.*, **КУРИ'ЛЬЩИЦА** *ж.* — тәмәкече.
**КУРИ'НЫЙ** — тавык...-ы; *куриный бульон* — тавык шулпасы. ◇ **Куриная грудь** *мед.* — тар, чыгыңкы күкрәк.
**КУРИ'НАЯ СЛЕПОТА'** — 1. *мед.* тавык күзе; 2. *бот.* казаяк, сары чәчәк.
**КУРИ'ТЕЛЬНЫЙ** — 1. тәмәке...-ы; *курительная бумага* — тәмәке кәгазе; 2. тәмәке тарту...-ы; *курительная комната* — тәмәке тарту бүлмәсе.
**КУРИ'ТЬ** *несов.* — 1. тарту, тәмәке тарту; 2. яндырып хуш ис тарату; 3. *спец.* куу; *спирт курят из картофеля* — спиртны бәрәңгедән куалар.
**КУРИ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. тартылу; *сырой табак плохо курится* — чи тәмәке начар тартыла (ягъни: чи тәмәке тартырга начар); 2. төтенләп тору; томанланып тору; *вдали курились овины* — еракта эвеннәр төтенләп торалар иде; *река курилась* — елга томанланып тора иде; 3. *страд.* тартылу; куылу.
**КУ'РИЦА** *ж.* (*мн.* куры) — 1. тавык; 2. тавык ите; *пирог с курицей* — тавык ите салып пешерелгән бөккән. ◇ **Мокрая курица** *разг.* — мәхлук, җебегән, булдыксыз

кеше. **Курам на смех** *разг.*— чиктән тыш мәгънәсез, тозсыз, тавыклар көләр. **Денег куры не клюют** *разг.*— акчасы бик күп.

**КУ'РИЯ** *ж.*— курия (кайбер буржуаз илләрнең сайлау системасында сословиеләренә, байлыкларына карап сайлаучылар бүленә торган разрядларның исеме).

**КУРКО'ВЫЙ** — чакмалы; *курковое ружьё* — чакмалы мылтык.

**КУ'РЛЫ** *звукоподраж. обл.*— торыйк-торыйк, кор-кор (торна тавышы).

**КУРЛЫ'КАТЬ** *несов. обл.*— торкылдау, торыйк-торыйк кычкыру (торна турында).

**КУ'РНИК** *м. обл.*— **1.** тавык кетәге; **2.** тавык ите бәлеше.

**КУРНО'Й** *устар.*— кара, моржасыз; *курная изба* — кара өй, моржасыз өй. ◇ **Курной уголь** — сумалалы ташкүмер.

**КУРНО'САЯ** *в знач. сущ. ж. нар.-поэт.*— үлем.

**КУРНО'СЫЙ** *разг.*— курнос борынлы, почык борынлы, тупый борынлы, кыска борынлы.

**КУРНУ'ТЬ** *однокр. простореч.*— суырып кую, суырып алу (тәмәкене бер генә тапкыр).

**КУРОВО'Д** *м.*— тавык үрчетүче.

**КУРОВО'ДСТВО** *ср. с.-х.*— **1.** *только ед.* тавык үрчетү; **2.** тавык үрчетү хуҗалыгы.

**КУРОВО'ДЧЕСКИЙ** *спец.* — тавык үрчетү...-ы; *куроводческое хозяйство* — тавык үрчетү хуҗалыгы.

**КУРО'К** *м.*— курок, тәтә, чакма.

**КУРОЛЕ'СИТЬ** *несов. простореч.*— шаяру, тавыш күтәрү, гауга күтәрү, җәнҗал чыгару.

**КУРОПА'ТКА** *ж. зоол.*— көртлек, кыр тавыгы, кыргавыл.

**КУРО'РТ** *м.*— курорт (1. табигый байлыклары буенча дәвалануга яраклы урын; **2.** шундый урынга салынган дәвалану йортлары).

**КУРО'РТНИК** *м.*, **КУРО'РТНИЦА** *ж. разг.*— курортта дәваланучы.

**КУРО'РТНЫЙ** — курорт...-ы; курортлар...-ы; *курортное управление* — курортлар идарәсе.

**КУРОСЛЕ'П** *м. бот.*— казаяк, сары чәчәк.

**КУ'РОЧКА** *ж.*— **1.** тавык; **2.** саз тавыгы (кош).

**КУРС** *м.*— **1.** курс, юл; *держать курс на юг* — көньякка таба юл тоту; *курс на индустриализацию страны* — илне индустрияләштерүгә курс тоту; **2.**курс; *он окончил курс в политехникуме* — ул политехникум курсын тәмам итте; *перейти на четвёртый курс* — дүртенче курска күчү; **3.** курс, кыйммәт, бәя; *курс рубля* — сумның курсы (кыйммәте, бәясе); **4.** *только мн.* курслар; *курсы по подготовке трактористов* — трактористлар хәзерләү курслары. ◇ **Быть в курсе** — хәбәрдар булу, хәбәрдар булып тору, белеп тору. **Держать в курсе** — хәбәрдар итеп тору, белдереп тору. **Войти в курс** — төшенү, төшенеп житү, аңлау. **Ввести в курс** — төшендерү, аңлату.

**КУРСА'НТ** *м.*— курсант (1. гаскәри мәктәп, гаскәри курслар укучысы; **2.** курсларда укучы).

**КУРСА'НТКА** *ж.*— курсантка, курсларда укучы кыз.

**КУРСА'НТСКИЙ** — курсантлар...-ы; *курсантская бригада* — курсантлар бригадасы.

**КУРСИ'В** *м. тип.*— курсив (язма хәрефкә охшаган басма хәреф, типография хәрефе).

**КУРСИ'ВНЫЙ** *тип.*— **1.** курсив...-ы; *курсивный шрифт* — курсив хәрефе; **2.** курсивтан җыелган; *курсивная строка* — курсивтан җыелган юл.

**КУРСИ'РОВАТЬ** *несов.*— йөреп тору (билгеле пунктлар арасында); *между Москвой и Ялтой курсируют автобусы* — Москва белән Ялта арасында автобуслар йөреп тора.

**КУРСИ'СТ** *м.*, **КУРСИ'СТКА** *ж. дорев.*— курсларда укучы.

**КУРСО'ВКА** *ж.*— курсовка (курортта дәвалану һәм туклануга хокук бирә торган документ).

**КУРСОВО'Й** — курс...-ы; курслар...-ы; *курсовое собрание* — курс җыелышы; *курсовая канцелярия* — курслар канцеляриясе.

**КУРСО'РНЫЙ** *педаг.* — йөгерек, күз йөртеп...; *курсорное чтение* — йөгерек уку, күз йөртеп уку.

**КУРТА'Ж** *м. торг.*— куртаж (сату-алу эшендә арадашлык иткән өчен түләнә торган акча).

**КУРТИЗА'НКА** *ж. книж. устар.*— куртизанка, аксөяк фахишә.

**КУРТИ'НА** *ж.*— **1.** клумба, гөлләр түтәле, чәчәклек; **2.** *воен. устар.* куртина (крепостьның бастионнар арасындагы өлеше).

**КУ'РТКА** *ж.*— куртка (ирләрнең кыска тышкы киеме).

**КУ'РФЮРСТ** *м. истор.*—курфюрст (Германиядә феодализм чорында император сайлауга катнашу хокукы булган князь).

**КУРЧА'ВИТЬСЯ** *несов. разг.*— бөтеркәләнү, бөдрәләнү, көдрәләнү.

**КУРЧАВОВОЛО'СЫЙ** — бөдрә чәчле; көдрә чәчле.

**КУРЧА'ВОСТЬ** *ж. мн.* нет — бөдрәлек, көдрәлек.

**КУРЧА'ВЫЙ** — **1.** бөдрә, көдрә; *курчавые волосы* — бөдрә чәч; **2.** бөдрә чәчле, көдрә чәчле; *курчавый парень* — бөдрә чәчле егет; **3.** бөдрә йонлы, көдрә йонлы; *курчавый баран* — бөдрә йонлы тәкә.

**КУРЧО'НОК** *м.* (*мн.* курчата) *обл.*— чебен, чебеш.

**КУ'РЫ: строить куры** *шутл.*—хатын-кыз артыннан йөрү.

**КУРЬЁЗ** *м.*— **1.** кызык вакыйга, көлке, мәзәк; **2.** *разг.* сирәк очрый торган әйбер, кызыклы әйбер. ◇ **Ради курьёза** — кызык өчен, мәзәк өчен.

**КУРЬЁЗНО** *нареч.* — кызык итеп, көлке итеп, мәзәк итеп.

**КУРЬЁЗНЫЙ** — кызык, көлке, мәзәк, кызыклы, көлкеле.

**КУРЬЕ'Р** *м.*— **1.** курьер, йомышка йөрүче, эш кәгазьләре ташучы; **2.** курьер (дипломатия почтасын йөртүче).

**КУРЬЕ'РСКИЙ** — **1.** курьерлык...-ы, йомышка йөрүче...-ы; *курьерские обязанности* — курьерлык вазифалары; **2.** курьерский, тиз йөрешле; *курьерский поезд* — тиз йөрешле поезд, курьерский поезд.

**КУРЬЕ'РША** *ж.*— курьерша, йомышка йөрүче хатын-кыз.

**КУРЯ'ТИНА** *ж. мн.* нет, *разг.*— тавык ите.

**КУРЯ'ТНИК** *м.*— **1.** тавык кетәге; **2.** *обл.* тавык белән сәүдә итүче; **3.** *обл.* тавык тибүче, тавык аулаучы (мәсәлән, карчыга).

**КУРЯ'ТНИЦА** *ж. обл.*— тавык аулаучы, тавык тотучы (мәсәлән, төлке, эт).

**КУРЯ'ТНЫЙ** *обл.*— тавык...-ы, йорт кошлары...-ы; *курятная торговля* — тавык сәүдәсе, йорт кошлары сәүдәсе.

**КУРЯ'ЧИЙ** *обл.*— к. куриный.

**КУС** *м. обл.*— кисәк, зур кисәк.

**КУСА'КА** *м.* и *ж. простореч.*— **1.** тешләүче, тешләк; **2.** *перен. фам.* ачучан кеше, усал кеше, бәйләнчек кеше.

**КУСА'ТЬ** *несов.*— **1.** тешләү; *эта собака не кусает детей* — бу эт балаларны тешләми; **2.** чәйнәү; *кусать губы от злости* — ачудан иреннәрне чәйнәү; **3.** талау; *всю ночь его кусали блохи* — төн буе аны борчалар талаган; **4.** чагу (кычыткан, корт турында); **5.** (*перерезывать щипцами*) кысып өзеп алу.

**КУСА'ТЬСЯ** *несов.*— **1.** тешләү; *собака кусается* — эт тешли; **2.** тешләшү; *собаки кусаются* — этләр тешләшә; **3.** *разг. фам.* үтә кыйммәт булу, теш үтмәү; *вещица хороша, да не купишь* — *кусается* — әйбере яхшы, ләкин сатып ала алмассың — үтә кыйммәт.

**КУСА'ЧКИ** *ед.* нет, *тех.*— каргаборын (келәшчә).

**КУСИ'** *межд. разг.*— эсс! (этне өстерү ымлыгы).

**КУСИ'ЩЕ** *м. разг.*— бик зур кисәк.

**КУСКОВО'Й** — кисәкле, шакмаклы; *кусковое мыло* — кисәкле сабын; *кусковой сахар* — шакмаклы шикәр.

**КУСНУ'ТЬ** *однокр. разг.*— тешләп алу.

**КУСО'К** *м.*— **1.** (*часть чего-н.*) кисәк, өлеш; *изрезать что-н. на куски* — берәр нәрсәне кисәкләргә (өлешләргә) кискәләү, турау; **2.** шакмак, кисәк; *кусок сахару* — бер шакмак шикәр; **3.** (*ломоть*) кисәк, телем, сынык; *кусок хлеба* — бер телем (бер сынык) икмәк; *кусок арбуза* — бер телем карбыз; **3.** калҗа; *кусок мяса* — бер калҗа ит; **4.** (*отрез, штука материи*) оч, кисәк; *кусок холста* — бер оч киндер; **5.** (*пропитание*) тамак, азык; *я не за кусок свой боюсь...* — мин үземнең тамагым өчен курыкмыйм...

**КУСО'ЧЕК** *м. разг.*— кечкенә кисәк, кечкенә телем, кечкенә өлеш, кечкенә шакмак.

**КУСТ** I *м. бот.* — куак. ◇ **Спрятаться в кусты** *разг. ирон.*— шүрләү, качу, сызу.

**КУСТ** II *м. спец* — куст, берләшмә.

**КУСТА'РНИК** *м. бот.*— **1.** куак; **2.** *собир.* куаклык.

**КУСТА'РНИКОВЫЙ** *бот.*— куак...; *кустарниковое растение* — куак үсемлек.

**КУСТА'РНИЧАТЬ** *несов. разг.*— **1.** кустарьлык итү, кул һөнәре белән шөгыльләнү; **2.** *пренебр.* таркау эшләү, примитив юл белән эшләү, тәртипсез эшләү.

**КУСТА'РНИЧЕСТВО** *ср. мн.* нет, *пренебр.*— кустарьчылык,囗 эштә примитивлык, эштә оешмаганлык.

**КУСТА'РНО** *нареч. пренебр.*— системасыз, примитив юл белән.

**КУСТА'РНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *пренебр.*— системасызлык, примитивлык.

**КУСТА'РНЫЙ** — **1.** кустарь...; *кустарная промышленность* — кустарь промышленность; **2.** *перен. пренебр.* гади, примитив, системасыз; *кустарные приёмы в работе* — эштә примитив алымнар.

**КУСТА'РЩИНА** *ж. мн.* нет, *разг. пренебр.*— к. кустарничество.

**КУСТА'РЬ** *м.*— кустарь, вак һөнәрче.

**КУ'СТИК** *м.*— кечкенә куак.

**КУСТИ'СТОСТЬ** *ж. мн.* нет — тармаклылык.

**КУСТИ'СТЫЙ** — тармаклы, күп тармаклы; *кустистая рожь* — тармаклы арыш.

**КУСТИ'ТЬСЯ** *несов.*— тармаклану, тармаклар җибәрү.

**КУСТО'ВКА** *ж. мн.* нет, *с.-х.*— кустовка (арышның тармаклы сорты).

**КУСТОВО'Й** I — куакланып үсә торган, куак булып үсә торган; тармакланып үсә торган.

**КУСТОВО'Й** II *спец.*— куст...-ы; *кустовое объединение* — куст берләшмәсе.

**КУСТООБРА'ЗНЫЙ** *книж.*— куаксыман.

**КУСТО'ЧЕК** *м. разг.*— к. кустик.

**КУСТЫ'** *мн.*— куаклык, әрәмә; *соловей поёт в кустах* — сандугач куаклыкта (әрәмәдә) сайрый. ◇ **Прятаться в кусты** — к. куст I.

**КУ'ТАТЬ** *несов.*— урау, чорнау, төрү.

**КУ'ТАТЬСЯ** *несов. разг.*— урану, чорналу, төрену.

**КУТА'ФЬЯ** *ж. обл.*— шыксыз киенгән хатын („борчак чүмәләсе" диләр).

**КУТЁЖ** *м.*— типтерү, әйттерү, эчү мәҗлесе.

**КУТЁНОК** *м.* (*мн.* кутята) *простореч.*— эт баласы, көчек.

**КУТЕРЬМА'** *ж. мн.* нет, *разг.*— ыгызыгы, шау-шу, гауга, чуалыш, тәртипсезлек.

**КУТИ'КУЛА** *ж. бот.*— кутикула (үсемлек сабакларының, ботакларының иң очындагы юка ярысы).

**КУТИ'ЛА** *м. разг.*— типтерүче, эчкече.

**КУТИ'ТЬ** *несов.*— **1.** типтерү, әйттерү, эчү; **2.** *разг. шутл.* күңел ачу, кәеф-сафа сөрү.

**КУТНУ'ТЬ** *однокр. разг.*— типтереп алу, әйттереп алу.

**КУТУ'ЗКА** *ж. простореч. фам.* — төрмә.
**КУТЬЯ'** *ж.* — баллы ботка, йөземле дөге боткасы (православныйларда дин йолаларын үтәгәндә ашыйлар).
**КУХА'РКА** *ж.* — кухарка, аш пешерүче хезмәтче.
**КУХА'РНИЧАТЬ** *несов. простореч.* — аш пешерү, аш пешерү белән шөгыльләнү.
**КУ'ХАРЬ** *м. обл.* — повар, аш пешерүче.
**КУХМИ'СТЕР** *м. устар.* — кухмистер (1. оста повар; 2. кечкенәрәк ресторан яки ашханә хуҗасы).
**КУ'ХНЯ** *ж.* — 1. кухня, аш өе; 2. аш пешерү өчен кулланыла торган прибор (мәсәлән, керосинка); 3. ашамлыклар, ашлар; 4. *перен. разг. фам. презрит.* хәйләләр, караңгы эшләр.
**КУ'ХОННЫЙ** — 1. кухняда эшләүче; 2. кухня...-ы; *кухонный нож* — кухня пычагы.
**КУ'ЦЫЙ** I — 1. *(о животном)* койрыксыз; көтек койрыклы; 2. *(об одежде)* кыска, кыска чабулы; 3. *перен. разг. ирон.* житкелексез, өтек, тар; *куцая буржуазная конституция* — өтек буржуаз конституция.
**КУ'ЦЫЙ** II *м. обл. нар.-поэт.* — куян.
**КУ'ЧА** *ж.* — 1. өем; *куча песку* — ком өеме; 2. *разг. фам.* бер көтү, бик күп; *у них куча детей* — аларның балалары бер көтү. ◇ **Валить всё в одну кучу** *разг.* — барын бер казанга тутыру (төрле күренешләрне бергә бутау).
**КУЧЕВО'Й**: **кучевые облака** — төркем-төркем болытлар.
**КУ'ЧЕР** *м.* — кучер, ат тотучы.
**КУЧЕРСКО'Й** — кучер...-ы; кучерлар...-ы; *кучерской кафтан* — кучер чикмәне.
**КУЧЕРЯ'ВИТЬСЯ** *несов. обл.* — бөтеркәләнү, бөдрәләнү, кодрәләнү.
**КУЧЕРЯ'ВЫЙ** *обл.* — к. кудрявый.
**КУ'ЧКА** *ж.* — 1. өем, кечкенә өем, өемчек; 2. төркем, кечкенә төркем.
**КУ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *спец.* — куелык, ешлык; *кучность попаданий пуль* — пуляләр тиюнең куелык, ешлык дәрәҗәсе.
**КУ'ЧНЫЙ** *спец.* — куе, еш; *кучный полёт дроби* — ядрәләрнең куе булып очуы.
**КУШ** I *м. разг.* — зур сумма акча, зур табыш, зур взятка, зур калҗа.
**КУШ** II *межд. разг.* — ят, тынич ят! (этка ятарга кушу ымлыгы).
**КУША'К** *м.* — пута, билбау.
**КУ'ШАНЬЕ** *ср.* — ашамлык, аш.
**КУ'ШАТЬ** *несов.* — ашау.
**КУШЕ'ТКА** *ж.* — кушетка (диванның бер төре).
**КУ'ЩА** *ж. церк. книж. поэт. устар.* — чатыр, куыш, күләгәле урын.
**КУЩЕ'НЬЕ** *ср. мн.* нет, *бот.* — тармаклану.
**КШ** *межд.* — көш-көш (кош куркыту ымлыгы).
**КЫС-КЫС** *межд.* — к. кис-кис.
**КЮВЕ'Т** *м. воен. тех.* — кювет (1. крепость стенасы янында су белән тутырылган канау; 2. яңгыр, кар суларын агызып җибәрү өчен гади юл һәм тимер юл буена казылган канау).
**КЮВЕ'ТКА** *ж.* — кюветка (1. фотография пластинкаларын һәм рәсемнәрен юу һәм эшкәртү өчен кулланыла торган озынча сай савыт; 2. керосин лампасының чөлтәре).
**КЮРАСО'** *ср. нескл.* — кюрасо, апельсин ликёры (эчемлек).

# Л

**ЛАБА'З** *м.* — 1. *устар.* лабаз (базарда бертекле ашлык, он сату урыны — ябык бина); 2. *обл.* лапас.
**ЛАБА'ЗНИК** *м. устар.* — лабазник (1. лабаз тотучы, лабаз хуҗасы; 2. лабазда сату итүче).
**ЛАБА'ЗНЫЙ** *устар.* — 1. лабазда ..., лабаз ... -ы; *лабазная торговля* — лабазда сату итү; *лабазное помещение* — лабаз бинасы; 2. *перен.* тупас, әшәке, начар, пычрак; *лабазная брань* — начар сүзләр әйтеп сүгенү.
**ЛАБИАЛИЗА'ЦИЯ** *ж. лингв.* — лабиализация, иренләштерү; иренләштерелү.
**ЛАБИАЛИЗОВА'ТЬ** *сов.* и *несов. лингв.* — лабиальләштерү, иренләштерү (сузык авазны, мәсәлән, „у", „ү" авазларын һәм шул авазлар алдыннан килгән кайбер тартык авазларны, әйткәндә иреннәрне очлайту, бөрештерү).
**ЛАБИАЛИЗОВА'ТЬСЯ** *сов.* и *несов. лингв.* — 1. лабиальләшү, иренләшү; 2. *страд.* лабиальләштерелү, иренләштерелү.
**ЛАБИА'ЛЬНЫЙ** *лингв.* — лабиаль, ирен ...-ы; *лабиальные звуки* — лабиаль авазлар, ирен авазлары (иреннәр белән әйтелә торган тартык авазлар, мәсәлән, „п", „б" авазлары).
**ЛАБИРИ'НТ** *м. книж.* — лабиринт (1. борынгы Грециядә һәм Египетта — бик күп бүлмәләре һәм буталчык коридорлары булган зур бина, сарай; 2. *перен.* белмәгән кешегә юл табып чыгуы читен булырлык итеп катлаулы һәм буталчык системада салынган бина һ. б.; 3. паркта буталчык юллар, сукмаклар системасы; 4. *перен.* катлаулылык, буталчыклык, чуалчыклык; 5. *анат.* колакның эчке өлеше).
**ЛАБОРА'НТ** *м.*, **ЛАБОРА'НТКА** *ж.* — лаборант (1. лабораторияләрдә эшләүче гыйльми яки техник сотрудник; 2. профессорның, укытучының лаборатория занятиеләре алып баручы ярдәмчесе).
**ЛАБОРАТО'РИЯ** *ж.* — лаборатория (1. техник яки гыйльми тикшерену тәҗрибәләре алып бару өчен җайланган махсус бина; 2. *перен. книж.* нинди дә булса бер

эшнең, эшчәнлекнең катлаулы эчке төзелеше; *лаборатория поэта* — шагыйрьнең лабораториясе.

**ЛАБОРАТО'РНЫЙ** — лаборатория ...-ы, лабораториядә үткәрелә торган, лабораториядә ясала торган; *лабораторные опыты* — лабораториядә үткәрелә торган тәҗрибәләр (сынаулар). ◇ **Приготовленный лабораторным путём** — лабораториядә хәзерләнгән.

**ЛАБРАДО'Р** *м.* — лабрадор (кыр шпатының бер төре; биналар бизәү өчен кулланыла).

**ЛА'ВА** I *ж.* — лава (1. янар таудан атылып чыга торган, эрегән тау токымнары массасы; 2. *перен.* алга барганда очраган барлык комачауларны себереп ташлый торган көч, масса).

**ЛА'ВА** II *ж. воен.* — лава (атлы казакларда кулланылган атака ысулы).

**ЛА'ВА** III *ж. горн.* — лава (забойда ташкүмер катламы).

**ЛА'ВА** IV *ж. чаще мн. обл.* — басма, кечкенә күпер (мәсәлән, тар елга яки канау аркылы салынган басма).

**ЛАВИ'НА** *ж.* — 1. лавина (тау башларыннан ишелеп төшә торган зур боз яки кар кисәкләре); 2. *перен.* бик күп, ... өеме; *накопилась лавина неразобранных бумаг* — тикшерелмәгән кәгазьләр өеме җыелган. ◇ **Полки двинулись сплошной лавиной** — полклар тоташ бер лавина булып кузгалып киттеләр.

**ЛАВИ'РОВАТЬ** *несов.* — 1. лавировать итү (а. *мор.* җилкәнне җайлап, җилгә каршы борыла-сарыла алга бару; җилне әле сулда, әле уңда калдырып сынык линия буенча бару; б. *перен.* комачаулык ясый торган кыенлыкларны читләтеп үтә-үтә алга бару яки оста рәвештә аларны ерып чыгу); 2. *перен. презрит.* җил ягына җайлану; җил кая иссә, шул якка борылу; койрык болгау; әле бер кешегә, әле икенче кешегә ярарга тырышу.

**ЛА'ВКА** I *ж.* — ян сәке, уша; зур скамья.

**ЛА'ВКА** II *ж.* — кибет. ◇ **Кондитерская лавка** *устар.* — кафе(нең бер төре). **Модная лавка** *устар.* — модалар мастерское.

**ЛА'ВОВЫЙ** *геол. геогр.* — лава...-ы, лавадан барлыкка килгән; *лавовое озеро* — лава күле.

**ЛА'ВОЧКА** I *ж. разг.* — 1. кечкенә кибет; 2. кечкенә скамья.

**ЛА'ВОЧКА** II *ж. разг.* — к. лавка II. ◇ **Устроили там лавочку** *простореч.* — бер шайка җыелган шунда. **Это одна лавочка** *простореч.* — болар барысы да бер шайка (бергәләп җинаятьләр эшләүче кешеләр шайкасы турында). **Надо закрыть эту лавочку** *простореч.* — бу эшәкелекләрне бетерергә кирәк. **Перебивать лавочку** *простореч. шутл.* — кеше сыныгын авызыннан тартып алу.

**ЛА'ВОЧНИК** *м. устар.* — кибетче (кибет хуҗасы).

**ЛА'ВОЧНИЦА** *ж. устар.* — 1. к. лавочник; 2. *простореч.* кибетче хатыны.

**ЛА'ВОЧНЫЙ** — 1. кибеттә сатыла торган, кибет...-ы; *лавочные товары* — кибеттә сатыла торган товарлар; 2. кибет...-ы; *лавочная комиссия* — кибет комиссиясе.

**ЛАВР** *м.* — 1. лавр, дәфнә агачы (мәңге яшел яфраклы, хуш исле агач); 2. *чаще мн. книж. ритор.* к. лавровый венок; 3. *только мн. перен.* шөһрәт, уңыш, дан, дәрәҗә; *пожинать лавры* — дан казану. ◇ **Почить на лаврах** — рәхәт һәм тыныч яшәү, уңышлардан тынычланып яту (ирешелгән зур уңышлар белән тынычланып, артык алга омтылмау).

**ЛА'ВРА** *ж. церк. истор.* — лавра (зур монастырь).

**ЛАВРО'ВЫЙ, ЛА'ВРОВЫЙ** — лавр...-ы; *лавровая роща* — лавр урманчыгы. ◇ **Лавровый венок (венец)** *торж. поэт.* — җиңү таҗы (лавр яфракларыннан үрелгән венок — җиңү, өстен чыгу символы). **Лавровый лист** — лавровый лист (ашка тәм кертү өчен салына).

**ЛАГ** *м. мор.* — 1. лаг (судноның йөрү тизлеген күрсәтә торган прибор); 2. судно борты.

**ЛА'ГЕРНЫЙ** — лагерь...-ы; лагерьда тору...-ы; *лагерный период* — лагерьда тору вакыты.

**ЛА'ГЕРЬ** *м.* — 1. лагерь; *военный лагерь* — хәрби лагерь; *пионерский лагерь* — пионерлар лагере; 2. *перен.* группировка, лагерь, як; *международный лагерь мира, демократии и социализма* — халыкара тынычлык, демократия һәм социализм лагере; *антиимпериалистический лагерь* — антиимпериалистик лагерь, империализмга каршы көрәшүче лагерь; *это человек не нашего лагеря* — бу безнең лагерь кешесе түгел, бу безнең яклы кеше түгел; 3. *перен.* аерым-аерым төркем; *дворяне и в большой и в малой зале группировались лагерями* (Л. Толстой) — дворяннар зур залда да, кечкенә залда да аерым-аерым төркемнәргә бүленгәннәр иде. ◇ **Снять лагерь** *воен.* — позициядән китү. **Обступить лагерем** *воен.* — төрле яктан камап алу. **Действовать на два лагеря** — икейөзле булу, ике яклы булу, ике якка да эшләү.

**ЛАГУ'НА** *ж.* — 1. лагуна; диңгез култыгы; 2. лагуна (а. диңгездән аерылып барлыкка килгән кечкенә күл; б. *геогр.* мәрҗән утраулары арасындагы сулык).

**ЛАГУ'ННЫЙ** *геогр.* — лагунадагы...; лагуналы; *лагунные острова* — лагуналы утраулар; *лагунные рифы* — лагунадагы рифлар.

**ЛАД** *м.* — 1. *только ед. простореч.* (*согласие, дружба*) татулык, дуслык; 2. *муз.* (*клавиши гармоники*) тел; 3. *охот.* тән төзелеше; *лады лягавой собаки* — ау этенең тән төзелеше. ◇ **В ладу или в ладах** *разг.* — дус булу, тату булу. **В лад** — бер-беренә ярашып, бер-беренә яраштырып, бертавыштан. **Ни складу, ни ладу** — рәте-чираты юк, рәтсез, бәйләнешсез. **На лад (идти, пойти)** *разг.* — уңайга (бару), уңышлы (бару); *на лад их дело не пойдёт* — аларның эше уңайга бармас. **На все лады** — төрлечә. **На старый лад** — искечә.

**ЛА'ДА** *м.* и *ж. нар.-поэт.* — сөйгән яр; хатын; ир.

**ЛА'ДАН** *м. мн.* нет — ладан (чиркәүдә гыйбадәт вакытында төтәтү өчен кулланыла торган саргылт яки кызгылт төстәге хуш исле сумала). ◇ **Дышать на ладан** *перен. разг.* — үләр хәлгә җитү, бетерешү, җаны уч төбендә генә булу. **Бояться, как чорт ладана, бежать, как чорт от ладана** *разг. устар.* — шайтан яшеннән курыккандай курку, шайтан яшеннән качкандай качу (куркып качу мәгънәсендә).

**ЛА'ДАНКА** *ж.* — 1. *рел.* ладанка, бөти (ладан, тылсым кебек нәрсәләр салып муенга тагып йөртелә торган бөти); 2. *разг.* ладанка (а. паразитларны агулый торган матдә салып янда йөртелә торган кечкенә янчык; б. ладан яндыра торган кечкенә савыт, чүлмәк).

**ЛА'ДАННЫЙ** — ладан ... -ы; *ладанный дым* — ладан төтене.

**ЛАДЕ'ЙНЫЙ** *шахм.* — ладья...-ы, ладья белән...; *ладейный ход* — ладья белән йөрү.

**ЛА'ДИТЬ** *несов.* — 1. *разг.* (*жить согласно, быть в ладу*) тату тору, дус тору, килешеп тору; 2. *обл.* (*приводить в порядок*) төзәтү, җайлау, рәткә салу, рәтләү; 3. *обл. муз.* (*настраивать*) көйләү; 4. *простореч.* (*намереваться, готовиться*) хәзерләнү, җыену; ниятләү, чамалау; исәп тоту; 5. *простореч.* (*стараться*) тырышу,... турында уйлау; 6. *простореч.* (*твердить, повторять*) кабатлау, кабатлап тору, кабатлап әйтү, кабат-кабат әйтү, такылдау; *ладит одно и то же* — бер үк нәрсәне кабат-кабат әйтә (кабатлап әйтә). ◇ **Он всё своё ладит** — ул һаман үзенекен сөйли, ул һаман үзенекен такылдый.

**ЛА'ДИТЬСЯ** *несов.* — 1. *разг.* уңайга бару, җайлану, пешү (эш турында); *дело у него не ладится* — аның эше уңайга бармый; 2. *обл.* сөйләшү, килешү; *ладились по три рубля с воза* — йөген өчәр сумнан сөйләшкән идек; 3. *страд. обл.* төзәтелү, җайлану, рәткә салыну, рәтләнү; *лодка ладится* — көймә төзәтелә.

**ЛАДКО'М** *нареч. простореч. фам.* — дус кына, тату гына, килешеп кенә.

**ЛА'ДНО** *нареч. простореч.* — 1. яхшы, яхшы итеп, уңайлы итеп, туры китереп; *ладно сшитый пиджак* — яхшы (туры китереп) тегелгән пиджак; 2. дус, тату; *жить ладно* — дус яшәү; 3. уңышлы, яхшы; *дела идут ладно* — эшләр яхшы бара; 4. *в знач. утвердит. частицы* ярый (ризалык белдереп җавап кайтару).

**ЛА'ДНЫЙ** *простореч.* — 1. яраклы, ярарлык, уңайлы; *ладное дело* — яраклы эш; 2. эшлекле, яхшы, булган, булдыклы; *ладный парень* — эшлекле егет.

**ЛА'ДОНКА** — к. ладанка.

**ЛАДО'НКА** *ж. простореч.* — к. ладонь.

**ЛАДО'ННЫЙ** *анат.* — уч төбе...-ы; *ладонный мускул* — уч төбе мускулы.

**ЛАДО'НЬ** *ж.* — уч төбе. ◇ **Быть (видным) как на ладони** — уч төбендәге кебек, бик ачык булып күренү.

**ЛАДО'ШИ** *ед.* нет: **бить (ударять, хлопать) в ладоши** — кул чабу; кул чәбәкләү.

**ЛАДО'ШКА** *ж. разг. фам.* — к. ладонь.

**ЛАДЫ'ГА, ЛАДЫ'ЖКА** — *к.* лодыга, лодыжка.

**ЛАДЬЯ'** *ж.* — 1. *поэт.* көймә (ишкәкле яки җилкәнле зур көймә); 2. *шахм.* ладья (шахмат фигурасы).

**ЛАЖ** *м. торг.* — лаж, өстәмә хак (биржада билгеләнгән курска өстәп бирелә торган хак).

**ЛАЗ** *м.* — 1. *обл.* к лазейка 1; 2. *спец.* авыз (пар казанында); 3. *охот.* җәнлекләр сукмагы (җәнлекләр үтеп йөри торган сукмак).

**ЛАЗАРЕ'Т** *м.* — лазарет (гаскәриләр өчен кечкенә больница).

**ЛА'ЗАТЬ** *несов.* — к. лазить.

**ЛАЗЕ'ЙКА** *ж.* — 1. (үтеп чыгарлык) тишек, тар юл; үтәрлек урын; 2. *перен.* котылу юлы, котылу чарасы (авыр хәлдән).

**ЛА'ЗИТЬ** *несов.* — 1. менү, менеп төшү, менеп-төшеп йөрү, менеп йөрү, үрмәләп менү, тырмашып менү, ябышып, тотынып менү (төшү), үрмәләү; *два раза лазил на Везувий* — ике тапкыр Везувийга менеп төштем (мендем); *вместе по заборам лазили* — бергә коймаларга менеп йөри торган идек; 2. кереп йөрү, үтү, керү; кереп-чыгып йөрү; *лазить в пролом стены* — стенадагы тишектән кереп-чыгып йөрү; *лазить в шалаш* — шалашка кереп йөрү, шалашка керү; *лазить в чужой карман* — кеше кесәсенә керү.

**ЛАЗО'РЕВКА** *ж. зоол.* — күк песнәк.

**ЛАЗО'РЕВЫЙ** *обл.* и *поэт.* — к. лазурный.

**ЛА'ЗСКИЙ** — лаз...-ы, лаз халкы ... -ы; *лазский язык* — лаз теле.

**ЛАЗУ'РЕВЫЙ** *поэт. устар.* — к. лазурный. ◇ **Лазуревый камень** *мин.* — к. ляпис-лазурь.

**ЛАЗУ'РНЫЙ** *поэт.* — сыек зәңгәр, аксыл зәңгәр, зәңгәрсу (төстәге).

**ЛАЗУ'РЬ** *ж. мн.* нет — 1. (*светлосиний цвет*) аксыл-зәңгәр (төс), аксыл-күк (төс); 2. *поэт.* (*цвет неба, моря*) зәңгәрлек; 3. (*краска*) лазурь, сыек зәңгәр буяу.

**ЛАЗУ'ТЧИК** *м. воен.* — лазутчик (дошманның тылына үтүче разведчик).

**ЛА'ЗЫ** *мн.* — лазлар, лаз халкы (Көньяк Кавказда һәм Төркиядә яшәүче халык).

**ЛА'ЗЯЩИЙ** — 1. үрмәләүче; *лазящие птицы* — үрмәләүче кошлар; 2. үрмәле, үрелеп үсә торган, уралып үсә торган; *лазящие растения* — үрмәле (үрелеп үсә торган) үсемлекләр.

**ЛАЙ** *м. мн.* нет — 1. (*собачий*) өрү; 2. *перен. простореч.* (*брань, ругань*) кычкырыну, акырыну, җикеренү, тиргәшү, өрү.

**ЛА'ЙБА** *ж. обл.* — лайба, зур көймә (палубалы, бер яки ике мачталы зур көймә).

**ЛАЙДА'К** *м. обл. бран.* — эшлексез, ялкау, иренчәк, түбән (кеше).

**ЛА'ЙКА** I *ж. зоол.* — лайка (төньякта — ау эте токымы).

**ЛА'ЙКА** II *ж. мн.* нет — лайка (йомшак күннәрнең бер сорты).

**ЛА'ЙКОВЫЙ** — лайка...-ы, лайкадан тегелгән; *лайковые перчатки* — лайкадан тегелгән перчатка.

**ЛАЙНСМЕ'Н** *м. спорт.* — лайнсмен (теннис яки футбол уенында — судья ярдәмчесе).

**ЛАК** *м.* — 1. лак; 2. *собир. (изделия)* лаклы әйберләр (агачтан, папье-машедан ясалган һәм лак белән капланган бизәкле әйберләр); 3. *перен.* тышкы ялтыравык. ◇ **Петербургский лак на неё наведён** (Тургенев) — Петербург аны бераз шомарткан.

**ЛАКА'ТЬ** *несов.* — эчү, ялап эчү (мәченең, этнең ялап эчүе турында).

**ЛАКЕ'Й** *м.* — 1. *дореволо. загр.* лакей; 2. *презрит.* лакей, ялчы, хуҗа кушканны үтәүче ялагай, юмакай, тәлинкә тотучы.

**ЛАКЕ'ЙСКАЯ** *в знач. сущ. ж. устар.* — лакейлар бүлмәсе.

**ЛАКЕ'ЙСКИЙ** — лакей...-ы, лакейлар ...-ы; *лакейские привычки* — лакейлар гадәте.

**ЛАКЕ'ЙСТВО** *ср. мн.* нет — 1. *устар.* лакейлык, лакей булып хезмәт итү; 2. *перен. презрит.* ялагайлык, юмакайлык; 3. *собир. устар.* лакейлар.

**ЛАКЕ'ЙСТВОВАТЬ** *несов.* — 1. *простореч. устар.* лакей булып хезмәт итү; 2. *перен. презрит.* ялагайлану, юмакайлану, тәлинкә тоту, хуҗа кушканны үтәү.

**ЛАКИРО'ВАННЫЙ** — 1. лакланган, лак йөгертелгән; 2. *только полн. формы. перен. книжн.* шома, шомартылган; *лакированный стиль* — шома стиль; 3. *перен.* тыштан ялтыравыклы, ялган.

**ЛАКИРОВА'ТЬ** *несов.* — 1. лаклау, лак белән каплау, лак сөртү; лак йөгертү; 2. *перен. неодобр.* шомартып күрсәтү, бизәп (артык матурлап) күрсәтү, яхшыртып күрсәтү.

**ЛАКИРОВА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. лаклану, лак белән каплану; 2. артык матурлап күрсәтелү, шомартып күрсәтелү, бизәп күрсәтелү.

**ЛАКИРО'ВКА** *ж. мн.* нет — 1. *(действие)* к. лакировать; 2. лак; *лакировка сошла* — лагы купкан; 3. *перен. устар.* тышкы матурлык, тышкы яктан шомару.

**ЛАКИРО'ВОЧНЫЙ** *спец.* — лаклау ... -ы; *лакировочная мастерская* — лаклау мастерское.

**ЛАКИРО'ВЩИК** *м. спец.* — 1. лакировщик, лаклаучы; . *перен. неодобр.* яхшыртып күрсәтүче, шомартып күрсәтүче, бизәп күрсәтүче (чынбарлыкны, хакыйкатьне).

**ЛА'КМУС** *м. хим.* — лакмус (1. зәңгәр төстәге буяу; 2. шундый буяу сеңдерелгән кәгазь; бу кәгазьне кислотага мансаң, кызыл төскә керә, селтегә мансаң, янадан зәңгәр төскә керә).

**ЛА'КМУСОВЫЙ** *хим.* — лакмус...-ы; лакмуслы, лакмус сеңдерелгән; *лакмусовая бумага* — лакмуслы кәгазь, лакмус сеңдерелгән кәгазь.

**ЛА'КОВЫЙ** — 1. лак ...-ы; *лаковый раствор* — лак эремәсе; 2. лаклы, лакланган; *лаковая обувь* — лаклы, лакланган аяк киеме; 3. *устар.* ялтыратылган, ялтырап тора торган, ялтыравыклы; *лаковый пол* — ялтыратылган идән.

**ЛА'КОМИТЬ** *несов. просторeч.* — ашату, сыйлау (тәмле ашамлыклар белән); *лакомить мальчика конфетами* — малайны конфет белән сыйлау.

**ЛА'КОМИТЬСЯ** *несов.* — сыйлану (тәмле ашамлыклар белән); *лакомиться вареньем* — варенье белән сыйлану.

**ЛА'КОМКА** *м.* и *ж. разг.* — тәмле тамак, тәмле әйберләр ашарга яратучы.

**ЛА'КОМСТВО** *ср.* — 1. *(сласти)* тәмле ашамлыклар, татлы ашамлыклар; 2. *(лакомое блюдо)* тәмле аш.

**ЛА'КОМЫЙ** — 1. *только полн. формы* тәмле, татлы; *лакомое блюдо* — тәмле аш; 2. *перен. преимущ. кратк. ф-мы, разг.* яратучан; *очень уж лаком до денег* — акчаны бик яратучан инде. ◇ **Лакомый кусок (кусочек)** *перен. разг.* — симез калҗа, майлы калҗа (күз кызарлык нәрсә).

**ЛАКОНИ'ЗМ** *м. книж.* — лаконизм, кыскалык, кыскалык һәм ачыклык (мәгънәне бернечә сүз белән ачык аңлатып бирү); *лаконизм речи* — сөйләмнең ачыклыгы һәм кыскалыгы.

**ЛАКОНИ'ЧЕСКИЙ** *книж.* — лаконик, кыска һәм ачык; кыска, аз сүзле; *лаконический ответ* — кыска һәм ачык җавап.

**ЛАКОНИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — кыскалык һәм ачыклык, аз сүзлелек, тәгәллек.

**ЛАКОНИ'ЧНЫЙ** — к. лаконический.

**ЛАКРИ'ЦА** *ж. мн.* нет, *бот. апт.*, **ЛАКРИ'ЧНИК** *м. бот.* — татлы тамыр (үсемлек үзе һәм аның тамыры).

**ЛАКРИ'ЧНЫЙ** *бот. апт.* — татлы тамыр...-ы, татлы тамырдан ясалган; *лакричный порошок* — татлы тамырдан ясалган порошок. ◇ **Лакричный корень** *бот.* — к. лакрица.

**ЛАКТА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *физиол.* — 1. *(выделение молока)* сөт бирү; *период лактации у коровы* — сыерның сөт бирү вакыты (чоры); 2. *(период кормления)* имезү чоры.

**ЛАКТОБАЦИЛЛИ'Н** *м. мн.* нет *бакт.* — лактобациллин (1. сөт әчеткеч бактерия; 2. шул бактерия ярдәмендә лабораториядә әчетеп хәзерләнгән катыкның бер төре).

**ЛАКТО'ЗА** *ж. мн.* нет, *хим.* — лактоза (сөт шикәре).

**ЛАКТО'МЕТР** *м. спец.* — лактометр (сөтнең сыйфатын билгеләү приборы).

**ЛАКУ'НА** *ж.* — 1. *анат.* чокырчык (организмда була торган чокырчыклар); 2. *филол.* буш урын, төшереп калдырылган урын (текстта).

**ЛАЛ** *м. поэт.* — рубин, кызыл якут (асылташ).

**ЛА'МА** I *ж. зоол.* — лама (Көньяк Америкада дөясыман хайван).

**ЛА'МА** II *м.* — лама (ламаистлар рухание).

**ЛАМАИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *рел.* — ламаизм (буддизмның Тибетта һәм Монголиядә таралган аерым бер формасы).

**ЛАМАИ'СТ** *м. рел.* — ламаист, ламаизм дивен тотучы.

**ЛАМАИ'СТСКИЙ** *рел.* — ламаизм...-ы; *ламаистское учение* — ламаизм тәгълиматы.

**ЛАМЕНТА'ЦИЯ** *ж. чаще мн. книж. ирон.* — зар, зарлану, сукрану.

**ЛА'МПА** *ж.* — лампа.

**ЛАМПА'ДА** *ж.* — 1. *церк.* лампада (икона алдына яндырып куела торган лампа); 2. *поэт.* лампа, яктырткыч.

**ЛАМПА'ДНЫЙ** — лампада...-ы; *лампадное масло* — лампада мае.

**ЛАМПА'С** *м.* — лампас (чалбар балагына буеннан-буена тегеп куела торган киң тасма).

**ЛАМПИО'Н** *м. спец.* — лампион (төсле кәгазьдән яки пыяладан ясалган һәм иллюминация өчен кулланыла торган кечкенә фонарь).

**ЛА'МПОВЩИК** *м.*, **ЛА'МПОВЩИЦА** *ж.* — лампачы (1. лампалар ясаучы; 2. лампалар белән яктырту эшен башкаручы).

**ЛА'МПОВЫЙ** — 1. лампа...-ы; *ламповое стекло* — лампа пыяласы; 2. *тех.* лампалы; *ламповый радиоприёмник* — лампалы радиоалгыч.

**ЛА'МПОЧКА** *ж.* — 1. кечкенә лампа; 2. электр лампасы. ◇ **Лампочка Ильича** — Ильич лампасы (электр лампасы).

**ЛАМУ'ТСКИЙ** — ламут...-ы, ламутлар...-ы; *ламутский язык* — ламут теле.

**ЛАМУ'ТЫ** *мн.* — ламутлар, ламут халкы (эвеннарның элеккеге исеме).

**ЛАНГУ'СТ** *м.*, **ЛАНГУ'СТА** *ж.* — лангуст (ашарга ярый торган диңгез кысласы).

**ЛАНДВЕ'Р** *м.* — ландвер (элекке Австриядә һәм элекке Германиядә — гаскәри хезмәткә өйрәтеп запаска чыгарылган һәм сугыш башлану белән армиягә алына торган кешеләр).

**ЛАНДКА'РТА** *ж. устар.* — географик карта.

**ЛАНДО'** *ср. нескл.* — ландо (дүрт кешелек экипаж).

**ЛАНДРИ'Н** *м. мн. нет, разг. устар.* — ландрин (конфетның бер төре).

**ЛАНДСКНЕ'ХТ** *м.* — 1. *истор.* ландскнехт (урта гасырларда Көнбатыш Европада — ялланган солдат); 2. *перен. презрит.* ялчы, хезмәтче.

**ЛАНДТА'Г** *м. полит. устар.* — ландтаг (Австриянең, Германиянең аерым өлкәләрендә иларә итү органы. 1952 нче елның азагында Германия демократик республикасында яңа административ округлар төзелү сәбәпле ландтаглар бетерелде).

**ЛАНДША'ФТ** *м. книж.* — 1. ландшафт, пейзаж, күренеш; *живописный ландшафт* — матур ландшафт (күренеш); 2. *геогр.* ландшафт (җир өсте формасы).

**ЛАНДША'ФТНЫЙ** *книж.* — 1. ландшафт...-ы; *ландшафтные зоны* — ландшафт зоналары; 2. ландшафт төшерелгән; *ландшафтная живопись* — ландшафт төшерелгән рәсемнәр.

**ЛАНДШТУ'РМ** *м.* — ландштурм (кайбер Көнбатыш Европа илләрендә сугыш вакытында үтә кирәк булганда гына армиягә алына торган, өченче чираттагы резервта булган кешеләр).

**ЛА'НДЫШ** *м. бот.* — ландыш, энҗе чәчәк.

**ЛА'НДЫШЕВЫЙ** — ландыш...-ы; энҗе чәчәк...-ы; *ландышевый запах* — ландыш исе.

**ЛАНИ'ТА** *ж. церк.-книж. поэт. устар.* — яңак.

**ЛА'НКА** *ж. охот.* — ана болан.

**ЛАНОЛИ'Н** *м. апт.* — ланолин (сарык йонын юганда чыга торган май; медицинада, косметикада һәм техникада кулланыла).

**ЛАНОЛИ'НОВЫЙ** *апт.* — ланолинлы, ланолиннан ясалган; *ланолиновый крем* — ланолинлы (ланолиннан ясалган) крем.

**ЛАНСИ'РОВАТЬ** *несов. книж. устар.* — тарату; җәелдерү; *лансировать слухи* — сүз тарату, хәбәр тарату, гайбәт тарату.

**ЛАНЦЕ'Т** *м. спец.* — ланцет (хирургиядә кулланыла торган үткен очлы ике йөзле пычак).

**ЛЖЕПРИСЯ'ГА** *ж. право., доревол., загр.* — ялган ант, ялган шаһитлек итү.

**ЛЖЕСВИДЕ'ТЕЛЬ** *м.*, **ЛЖЕСВИДЕ'ТЕЛЬНИЦА** *ж. книж. право* — ялган шаһит.

**ЛЖЕСВИДЕ'ТЕЛЬСКИЙ** *книж. право* — ялган шаһит ...-ы; *лжесвидетельские показания* — ялган шаһит күрсәтүләре.

**ЛЖЕСВИДЕ'ТЕЛЬСТВО** *ср. книж. право.* — ялган шаһитлек.

**ЛЖЕСВИДЕ'ТЕЛЬСТВОВАТЬ** *несов. книж. право* — ялган шаһитлек итү, ялган күрсәтүләр бирү.

**ЛЖЕУЧЕ'НИЕ** *ср. книж.* — ялган тәгълимат.

**ЛЖЕЦ** *м. книж.* — ялганчы, алдакчы.

**ЛЖИ'ВОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — ялганчылык, ялганлык.

**ЛЖИ'ВЫЙ** *книж.*— 1. ялганчы, алдакчы; *лживый человек* — ялганчы кеше; 2. алдаулы, ялган; *лживые слова* — ялган сүзләр.

**ЛИ** — 1. *вопрос. частица...* -мы? *далеко ли живёте?* — ерак торасызмы? 2. *союз* ...-мы икән; *не знаю, соберусь ли к вам* — белмим, мин сезгә бара алырмынмы икән; 3. ...-мы, ...-мы; *рано ль, поздно ли, но приду* — иртәме, соңмы, бер, килермен әле.

**ЛИА'НА** *ж. бот.*— 1. лиана (эссе якларда үсә торган үрмәле үсемлекләрнең гомуми исеме); 2. *перен.* урелеп үсә торган ботак, үрмәле ботак (мәсәлән, виноград ботагы).

**ЛИБЕРА'Л** *м.*, **ЛИБЕРА'ЛКА** *ж.*— либерал (1. либерализм яклы кеше; 2. либераллар партиясе члены; 3. *неодобр.* либеральлек күрсәтеп, ягъни ярамаган эшләргә юл куеп, эшкә зарар китерүче кеше; 4. *разг. неодобр.* принципсыз кеше).

**ЛИБЕРАЛИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *книж.*— либерализм (1. буржуаз революцияләр чорында промышленность буржуазиясенең интересларын чагылдырган политик һәм экономик карашлар системасы; империализм һәм пролетар революцияләр эпохасында либерализм тирән реакцион агымга әверелде һәм контрреволюция лагеренннан торып эшчеләр сыйныфына каршы ачыктан-ачык көрәш башлады; 2. *устар. ирон.* буржуазиянең ирек сөючән булып кылануы; 3. *неодобр.* принципсызлык, кимчелекләргә җиңелчел юл куючанлык). ◇ **Гнилой либерализм** — черек либерализм (принципсызлык, кимчелекләргә, ярамаган эшләргә юл куючанлык).

**ЛИБЕРА'ЛЬНИЧАТЬ** *несов.*—1. *устар. ирон. неодобр.* либеральлек күрсәтү (ирек сөючән булып кылану); 2. *неодобр.* (*попустительствовать*) либеральлек күрсәтү (ярамаган эшләргә юл кую, килешүчәнлек күрсәтү).

**ЛИБЕРА'ЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— либеральлек.

**ЛИБЕРА'ЛЬНЫЙ** — 1. либерадь, либераллларча ...; *либеральные реформы*— либераль реформалар; *либеральный взгляд* — либералларча караш; 2. либераллар ...-ы; *либеральная партия* — либераллар партиясе.

**ЛИБЕРТИ'** *ср. нескл. спец.* — либерти (йомшак ялтыравыклы материя).

**ЛИ'БО** *разделит. союз* — я, яисә, яки.

**ЛИБРЕТ(Т)И'СТ** *м.*, **ЛИБРЕТ(Т)И'СТКА** *ж. театр. литер.*— либреттист, либреттолар язучы.

**ЛИБРЕ'ТТО** *ср. нескл. театр.*— либретто (1. зур музыкаль әсәрнең сүз тексты; 2. *разг.* операның, пьесаның программада язылган кыскача эчтәлеге; 3. балет яки кинофильмның сюжет планы, сценарий схемасы).

**ЛИ'ВЕНЬ** *м.*— көчле яңгыр, коеп ява торган яңгыр

**ЛИ'ВЕР** I *м. мн.* нет, *кулин.* — үпкә-бавыр (суйган хайванныкы).

**ЛИ'ВЕР** II *м. спец.*— ливер (сыекча суырту өчен кулланыла торган махсус трубка).

**ЛИ'ВЕРНЫЙ** — үпкә-бавырдан хәзерләнгән, үпкә-бавырдан пешерелгән; *ливерная колбаса* — үпкә-бавырдан хәзерләнгән колбаса.

**ЛИ'ВМЯ** *нареч. разг.*: **ливмя лить** — чиләкләп кою; коеп яву.

**ЛИ'ВНЕВЫЙ** *спец.*— яңгыр ...-ы; *ливневые воды* — яңгыр сулары.

**ЛИВР** *м. истор.*—ливр (1. Франциядә иске көмеш акча; 2. Франциядә электә 0,5 *кг* чамасындагы үлчәү берәмлеге).

**ЛИВРЕ'Я** *ж. дореволюц.* и *загр.*— ливрея (швейцарлар, лакейлар, кучерлар кия торган укалы махсус кием).

**ЛИ'ГА** *ж. книж.*— лига (1. союз, җәмгыять; 2. *муз.* тоташ уйнарга тиешлекне күрсәтә торган билге).

**ЛИГАТУ'РА** *ж.*— лигатура (1. *хим.* алтын яки көмешкә эретеп катыштырылган металл; 2. *филол.* к. вязь; 3. *мед.* операция вакытында кан тамырларын бәйли торган ефәк җеп яки кетгут).

**ЛИГНИ'Н** *м. мн.* нет — лигнин (1. *апт.* үзагачтан ясалган мамык; 2. *хим.* үзагачта була торган углеродка бай матдә).

**ЛИГНИ'Т** *м. мн.* нет, *горн.*— лигнит (түбән сортлы соры ташкүмер).

**ЛИГРОИ'Н** *м. мн.* нет — лигроин (нефть куганда барлыкка килә торган продуктларның берсе, ягулык).

**ЛИ'ДЕР** *м.*— лидер (1. *полит.* политик партиянең яки иҗтимагый-профессиональ оешманың җитәкчесе; 2. *спорт.* ярышта алда баручы кеше).

**ЛИ'ДЕРСТВО** *ср. мн.* нет, *полит. спорт.*— лидерлык.

**ЛИДИ'РОВАТЬ** *несов. спорт.*— лидер булып бару, алда бару.

**ЛИЗА'НИЕ** *ср.*— 1. *только ед.* (*действие*) к. лизать; 2. *разг. фам. пренебр.* үбеш, үбү.

**ЛИЗА'ТЬ** *несов.*— 1. ялау; 2. *разг. фам. неодобр.* үбү. ◇ **Лизать руки (ноги, пятки)** *перен. разг. фам. презрит.*— кул (аяк, үкчә) ялау, ялагайлану, тәлинкә тоту.

**ЛИЗА'ТЬСЯ** *несов. разг. фам. неодобр.*— үбешү.

**ЛИ'ЗИС** *м. мед.*— лизис (йогышлы авыру белән авыручының температурасы акрынлап төшү вакыты).

**ЛИЗНУ'ТЬ** *однокр.*— ялап алу, ялап кую.

**ЛИЗОБЛЮ'Д** *м. разг. презрит.*— тәлинкә ялаучы, тәлинкә тотучы, ялагай.

**ЛИЗОБЛЮ'ДНИЧАТЬ** *несов. разг. презрит.*— тәлинкә ялау, тәлинкә тоту, ялагайлану.

**ЛИЗОБЛЮ'ДСТВО** *ср. мн.* нет, *разг. презрит.*— ялагайлык.

**ЛИЗО'Л** *м. мн.* нет, *апт.*— лизол (дезинфекция ясау өчен кулланыла торган махсус май).

**ЛИЗУ'Н** *м.*, **ЛИЗУ'НЬЯ** *ж. разг. фам. пренебр.*— үбешергә яратучан, үбешүчән, үбәргә яратучан.

**ЛИК** *м. книж.*— йөз, чырай; тышкы кыяфәт.

**ЛИКБЕ'З** *м.* (ликвидация безграмотности) —ликбез (грамотасызлыкны бетерү).

**ЛИКВИДА'ТОР** *м.*— 1. бетерүче; *ликви-*

*датор неграмотности* — грамотасызлыкны бетерүче; 2. *полит.* ликвидатор (ликвидаторлык яклы кеше).

**ЛИКВИДА'ТОРСКИЙ** — ликвидаторлык ...-ы, ликвидаторлар...-ы; *ликвидаторские настроения* — ликвидаторлык настроениеләре.

**ЛИКВИДА'ТОРСТВО** *ср. мн.* нет, *полит.*— ликвидаторлык (РСДРП эчендә 1908—1912 елларда булган реакцион меньшевистик агым. Ликвидаторлар пролетариатның революцион сыйнфый көрәшен һәм аның революциядәге авангардлык ролен инкарь итеп, пролетариатның легаль булмаган революцион партиясен бетерергә, партия эшен самодержавие законнары рамкаларында гына алып барырга, аны буржуазия интересларына буйсындырырга өндәделәр. Ликвидаторлар, буржуазиянең агентурасы булганга күрә, 1912 елны РСДРПдан куылдылар).

**ЛИКВИДАЦИО'ННЫЙ** *книж.* — ликвидация ...-ы; *ликвидационная комиссия* — ликвидация комиссиясе.

**ЛИКВИДА'ЦИЯ** *ж. книж.* — 1. ликвидация, бетерү, ябу; 2. юкка чыгару.

**ЛИКВИДИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. книж.*— 1. бетерү, ябу; 2. юкка чыгару.

**ЛИКВИДИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. книж.*— 1. бетү, ябылу; 2. *страд.* бетерелү, юкка чыгарылу, ябылу.

**ЛИКВИ'ДНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *фин. торг.*— реализацияләнүчәнлек, реализовать ителүчәнлек, акчага әйләндерелә алучанлык.

**ЛИКВИ'ДНЫЙ** *фин. торг.*— реализацияләнә ала торган, акчага әйләндерелә ала торган.

**ЛИКЕ'Й** *м. устар.*— к. лицей.

**ЛИКЁР** *м.*— ликёр (спиртлы эчемлекнең бер төре).

**ЛИКЁРНЫЙ** — ликёр...-ы; *ликёрный завод* — ликёр заводы.

**ЛИКОВА'ТЬ** *несов. книж. ритор.*— шатлану, куану.

**ЛИКОПО'ДИЙ** *м. мн.* нет — ликоподий (1. *бот.* споралы үсемлек; 2. *апт. тех.* шундый үсемлекнең спорасыннан ясалган порошок).

**ЛИ'КТОР** *м. истор.*— ликтор (1. борынгы Римда — югары администрация кешесен саклап йөрүче кеше; 2. *перен.* гаепле иптәшләрен чыбыклау вазифасын үтәүче бурса студенты).

**ЛИЛЕ'ЙНЫЙ** *поэт. устар.*— ап-ак, лалә кебек ак.

**ЛИЛЕ'Я** *ж. поэт. устар.*— к. лилия.

**ЛИЛИПУ'Т** *м.*, **ЛИЛИПУ'ТКА** *ж.*— 1. лилипут (бик кечкенә буйлы, балаларга охшаган кеше); 2. *перен.* кечкенә; *словарь-лилипут*— кечкенә сүзлек.

**ЛИЛИПУ'ТСКИЙ** — лилипут...-ы, лилипутлар...-ы; кечкенә; *лилипутский рост* — кечкенә буй.

**ЛИ'ЛИЯ** *ж. бот.* — лалә (үсемлек һәм аның чәчәге). ◇ **Водяная лилия** — төнбоек.

**ЛИЛОВЕ'ТЬ** *несов.*— аксыл шәмәхә төскә керү.

**ЛИЛО'ВЫЙ** — аксыл шәмәхә, миләүшә төсле.

**ЛИМА'Н** *м.*— лиман (елгаларның диңгезгә койган урыннарында барлыкка килгән култык).

**ЛИМБ** *м.*— лимб (1. *тех.* почмак үлчәгеч приборларда — градусларга бүлгәләнгән түгәрәк; 2. *мед.* күзнең тоташтыргыч катлавының тар, үтә күренмәле чите).

**ЛИМИ'Т** *м.*— лимит, чик норма.

**ЛИМИТИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.*— лимит билгеләү, чик норма билгеләү.

**ЛИМИТИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд.*— лимит билгеләнү, чик норма билгеләнү, чик куелу.

**ЛИМИ'ТНЫЙ** *спец.*— лимит...; *лимитные цены* — лимит бәяләр.

**ЛИМО'Н** *м.*— лимон (агачы һәм җимеше). ◇ **Выжатый лимон** *перен. разг. ирон.* — дәрмансыз, талантсыз кеше; җебегән, сәләте беткән, көче беткән.

**ЛИМОНА'Д** *м.*— лимонад (алкогольсез эчемлек). ◇ **Лимонад-газéс** *устар.*— газландырылган лимонад.

**ЛИМО'НИТЬ** *несов. арго* — чәлдерү, сугу (урлау мәгънәсендә).

**ЛИМО'ННИК** *м. бот.*— лимонник (1. тропикта үсә торган куак; 2. шундый куаклык).

**ЛИМО'НЬНИЧАТЬ** *несов. простореч. фам. ирон.* — к. любезничать.

**ЛИМО'ННЫЙ** — 1. лимон...-ы; *лимонное дерево* — лимон агачы; 2. лимонда төнәтелгән; *лимонная водка* — лимонда төнәтелгән аракы.

**ЛИМО'НОВКА** *ж. мн.* нет, *разг.*— лимон аракысы.

**ЛИМУЗИ'Н** *м.*— лимузин (автомобильнең бер төре).

**ЛИ'МФА** *ж. физиол.*— лимфа (организмдагы төссез сыекча).

**ЛИМФА'ТИК** *м. мед.*— рухсыз, дәртсез кеше.

**ЛИМФАТИ'ЧЕСКИЙ** — 1. *физиол.* лимфа...-ы; *лимфатические железы* — лимфа бизләре; 2. *перен. книж. устар.* рухсыз, дәртсез, сүлпән.

**ЛИНГВИ'СТ** *м.*, **ЛИНГВИ'СТКА** *ж.*— 1. лингвист, телче, тел белгече; 2. *разг.* күп телләр белүче.

**ЛИНГВИ'СТИКА** *ж.*— лингвистика, тел белеме, тел гыйлеме (тел турындагы фән).

**ЛИНГВИСТИ'ЧЕСКИЙ** — 1. лингвистик; *лингвистические исследования* — лингвистик тикшеренүләр; 2. лингвистик, тел...-ы; *лингвистические явления* — лингвистик күренешләр.

**ЛИНЕВА'ЛЬНЫЙ** — к. линовальный.

**ЛИНЁВАНЫЙ** *разг.*— к. линованый.

**ЛИНЕВА'ТЬ** *несов.*— к. линовать.

**ЛИНЕВА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— к. линоваться.

**ЛИНЁВКА** *ж.*— к. линовка.

**ЛИНЕ'ЕЧКА** *ж.*— кечкенә линейка, кечкенә сызгыч.

**ЛИНЕ'ЕЧНЫЙ** — 1. сызык(лар)...-ы, линейка(лар)...-ы; *линеечное производство* — линейкалар производствосы; 2. линейка...-ы,

сызгыч...-ы, линейкалар (сызгычлар) ясауга китә торган; *линеечный материал* — линейка материалы, линейкалар ясауга китә торган материал.

**ЛИНЕ'ЙКА** I *ж.* — 1. сызык; *писать по линейкам* — сызыклар өстеннән язу; 2. линейка, сызгыч; *деревянная линейка* — агач сызгыч; *логарифмическая линейка* — логарифмик линейка; 3. *воен.* линейка, сызык, лагерьның чиге.

**ЛИНЕ'ЙКА** II *ж.* — линейка (күп урынлы озын ачык экипаж).

**ЛИНЁК** I *м. разг.* — вак кара балык.

**ЛИНЁК** II *м. мор. истор.* — 1. к. линь II; 2. линёк (электә судноларда җәза биргәндә кулланылган сумалалы кыска бау).

**ЛИ'НЗА** *ж.* — 1. *анат.* күз ясмыгы; 2. *физ.* линза (кабарынкы яки батынкы йөзле оптик пыяла).

**ЛИ'НИЙКА** *ж. уменьш. разг.* — кечкенә сызык.

**ЛИ'НИЯ** *ж.* — 1. сызык; *провести линию* — сызык сызу; *линия фронта* — фронт сызыгы; 2. юнәлеш, юл; *линия полёта снаряда* — снарядның очу юнәлеше (юлы); 3. саф, рәт; *построить корабли в линию* — корабльләрне рәткә тезү; 4. линия, юл; *линия железной дороги* — тимер юл линиясе; *трамвайная линия* — трамвай линиясе, трамвай юлы; *воздушная линия* — һава юлы; *телефонная линия* — телефон линиясе; 5. *книж.* як; *по линии отца он мне приходится родственником* — атам ягыннан ул миңа кардәш туры килә; 6. *разг.* язмыш; *всякому даётся известная линия в жизни* — тормышта һәркемнең үзенә күрә язмышы була. ◇ **Работать по профсоюзной линии** — профсоюз өлкәсендә эшләү. **Линия сопротивления** *мех.* — каршылык юнәлеше. **По линии наименьшего сопротивления** — иң җиңел юлдан.

**ЛИНКО'Р** *м. воен. мор.* — линкор (зур сугыш корабле).

**ЛИНОВА'ЛЬНЫЙ** *спец.* — сызу...-ы; *линовальный цех* — сызу цехы; *линовальная машина* — сызу машинасы.

**ЛИНОВА'ЛЬЩИК** *м. спец.* — сызучы.

**ЛИНО'ВАНЫЙ** — сызыклы, сызылган.

**ЛИНОВА'ТЬ** *несов.* — сызу.

**ЛИНОВА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — сызылу.

**ЛИНО'ВЩИК** *спец.* — сызыклар сызучы, сызучы.

**ЛИНО'ЛЕУМ** *м. мн.* нет — линолеум (идәнгә җәелә торган калын клеенка яки махсус эшләнгән тукыма).

**ЛИНО'ЛЕУМОВЫЙ** — линолеум..., линолеум җәелгән; *линолеумовый пол* — линолеум (җәелгән) идән.

**ЛИНОТИ'П** *м. тип.* — линотип (хәреф җыю машинасы).

**ЛИНОТИПИ'СТ** *м. тип.* — линотипист, линотипта эшләүче (наборщик).

**ЛИНОТИ'ПИЯ** *ж. мн.* нет, *тип.* — линотипия (линотипта хәреф җыю).

**ЛИНОТИ'ПНЫЙ** *тип.* — линотип...-ы, линотипта җыелган; *линотипный набор* — линотипта җыелган набор.

**ЛИНЧ** *м.*: суд Линча — Линч суды (Америкада бернинди тикшерүсез һәм судсыз җәзалап, кыйнап үтерү, урам суды; бу суд негрларга карата кулланыла); закон Линча — Линч законы (Америкада реакцион буржуазия тарафыннан негрларга һәм революционерларга карата кулланыла торган урам суды, судсыз җәзалап, кыйнап үтерү гадәте).

**ЛИНЧЕВА'ТЬ** *сов.* и *несов.* — судсыз җәзалап, кыйнап үтерү, линчевать итү.

**ЛИНЧЕВА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — судсыз җәзалап үтерелү, линчевать ителү.

**ЛИНЬ** I *м. зоол.* — кара балык.

**ЛИНЬ** II *м. мор.* — бау, нечкә аркан (корабльнең кирәк-яракларына китә торган).

**ЛИ'НЬКА** *ж. спец.* — йон кою; ябага кою; төс алмаштыру; кабык салу (мәсәлән, елан).

**ЛИНЮ'ЧЕСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. уңучанлык, төсе китүчәнлек; 2. йон коючанлык, йон коючан булу, ябага коючанлык, ябага коючан булу; төс алмаштыручанлык, кабык салучанлык.

**ЛИНЮ'ЧИЙ** — 1. уңа торган, уңучан, төссезләнә торган, төсе тиз китә торган, төсен югалта торган, төсе китүчән; *линючий ситец* — уңа торган (төсе тиз китә торган) ситсы; *линючая краска* — уңучан буяу; 2. (*о животных*) йон(ын) коя торган, ябага(сын) коя торган, төс(ен) алмаштыра торган, кабыгын сала торган.

**ЛИНЯ'ЛЫЙ** — 1. *разг.* уңган, төссез; *линялая материя* — уңган материя; 2. (*о животных*) йонын койган, ябагасын койган, төсен алмаштырган; кабыгын салган.

**ЛИНЯ'ТЬ** *несов.* — 1. уңу, төс югалту, төссезләнү; *эта материя линяет* — бу материя уңа; 2. (*о животных*) йон кою, ябага кою; төс алмаштыру; кабык салу; 3. *перен. полит. презрит.* ренегатка әверелү, революцион позициядән чигенү.

**ЛИ'ПА** I *ж.* — юкә, юкәгач.

**ЛИ'ПА** II *ж. простореч. вульг. арго* — ялган (ялган кәгазь, ялган вәгъдә, ялган сүз һ. б.).

**ЛИ'ПЕЦ** *м. обл.* — 1. (*липовый мёд*) юкә балы; 2. (*медовый напиток*) әче бал.

**ЛИ'ПКА** *ж. разг.* — к. липа I. ◇ **Ободрать (облупить), как липку** *простореч. фам.* — ялангач калдыру (бөтен нәрсәсен талау).

**ЛИ'ПКИЙ** — 1. ябышучан, сыланучан, ябыша торган, сылана торган; ябышкак; *липкая грязь* — сылана торган пычрак; *липкий пот* — ябышкак тир; 2. *перен. разг. фам.* бәйләнчек.

**ЛИ'ПКОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. ябышучанлык, сыланучанлык, ябышкаклык; 2. *перен. разг. фам.* бәйләнчеклек.

**ЛИ'ПНИК** *м. обл.* — к. липняк.

**ЛИ'ПНУТЬ** *несов.* — 1. ябышу, сылану; *грязь липла к ногам* — аякларга пычрак сылана иде; *мокрая одежда липла к телу* — юеш кием тәнгә ябыша иде; 2. *перен. разг. фам.* бәйләнү, сагыз булу, ябышу; 3. *разг.* ябышу; *губы липнут* — иреннәр ябыша.

**ЛИПНЯ'К** *м. обл.* — юкәлек, юкә урманы.

**ЛИ'ПОВЫЙ** I — 1. юкә...-ы; *липовый*

*цвет* — юкә чәчәге; *липовый мёд* — юкә балы; 2. юкә...; *липовая доска* — юкә такта.

**ЛИ'ПОВЫЙ** II *простореч. вульг.*— 1. ялган; *липовый документ* — ялган документ; 2. *презрит.* начар, белемсез, талантсыз; *липовый учёный* — белемсез (начар) галим; *липовый писатель* — талантсыз (начар) язучы.

**ЛИПУ'ЧИЙ** — бәйләнчек, йөдәтүчән, тенкәгә тиючән.

**ЛИ'РА** I *ж.*— лира (1. *истор.* борынгы грекларда — кыллы музыка коралы; 2. *обл. этногр.* Украинада — күчмә җырчыларның клавишлы кыллы музыка коралы; 3. поэтик иҗатның, сәләтнең, илһамның, лирик поэзиянең символы). ◇ **Лира — птица** *зоол.*— к. лирохвост.

**ЛИ'РА** II *ж.*— лира (Италиядә һәм кайбер башка илләрдә акча берәмлеге).

**ЛИРИ'ЗМ** *м. мн.* нет — лиризм (1. сәнгать әсәренең лирик характерда булуы, тойгыларга, эмоцияләргә байлыгы; 2. лирик настроение, нечкә тойгыларга бирелү).

**ЛИ'РИК** *м. лит.* — 1. лирик, лирик шагыйрь; 2. *перен. разг.* лирик, лирик характерлы кеше, тойгыларга бирелүчән кеше, нечкә тойгылы кеше.

**ЛИ'РИКА** *ж. мн.* нет — лирика (1. поэзиянең эчке кичерешләрне, тойгыларны чагылдыра торган бер төре; 2. лирик әсәрләрнең барысы бергә; *лирика Пушкина* — Пушкинның лирикасы (барлык лирик әсәрләре); 3. кешенең эчке кичерешләрен, тойгыларын чагылдыра торган музыка; 4. *перен. разг. неодобр.* тойгыларга ирек бирү (тойгыларның акылга караганда өстенлек алуы).

**ЛИ'РИКО-ДРАМАТИ'ЧЕСКИЙ** — лирик-драматик; *лирико-драматическая поэма* — лирик-драматик поэма.

**ЛИ'РИКО-ЭПИ'ЧЕСКИЙ** *книж. устар.*— к. лиро-эпический.

**ЛИРИ'ЧЕСКИЙ** — лирик; *лирическая поэзия* — лирик поэзия; *лирическое сопрано* — лирик сопрано. ◇ **Лирическое отступление** — лирик чигенү (1. *лит.* төп сюжетның, теманың арасына кертеп язылган лирик шигырьләр; 2. *перен. разг. шутл.* сөйләшкәндә төп темадан читкә тайпылу). **Лирический беспорядок** — лирик тәртипсезлек (1. *лит. истор.* әсәр төзүдә әдәби кануннарны бозу; 2. *перен. разг. шутл.* гомумән тәртипсезлек).

**ЛИРИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— лириклык, эчке хисләргә бирелүчәнлек.

**ЛИРИ'ЧНЫЙ** — лирик, лирик настроениеле, эчке хисләргә бирелгән, күтәренке-эмоциональ.

**ЛИ'РНИК** *м. этногр. устар.*— лирник (Украинада — урыннан урынга күчеп йөреп лирада уйнаучы җырчы).

**ЛИ'РНЫЙ** *поэт. устар.*— лира...-ы; *лирный звук* — лира тавышы.

**ЛИРОХВО'СТ** *м. зоол.*— лира койрык (кош).

**ЛИ'РО-ЭПИ'ЧЕСКИЙ** *лит.*— лиро-эпик (лирик һәм эпик элементларны эченә алган әдәби әсәр турында әйтелә).

**ЛИС** *м. обл. устар.*— ата төлке.

**ЛИСА'** *м.* и *ж.*— 1. *ж.* к. лисица; 2. *м.* и *ж. перен.* төлке, юмакай (хәйләкәр мәгънәсендә); 3. *разг.* төлке мехы. ◇ **Лиса Патрикеевна** *нар.-поэт.*— хәйләкәр төлке (рус халык әкиятләрендә төлкене шулай атыйлар). **Лисой прикидываться (вертеться** и т. п.) *простореч.* — төлкеләнү, ялагайлану, юмакайлану, төрле хәйләләр корып алдарга тырышу.

**ЛИ'САНЬКА** — к. лисонька.

**ЛИСЁНОК** *м.* (*мн.* лисята) — төлке баласы.

**ЛИ'СИЙ** — 1. төлке...; *лисья шуба* — төлке тун; 2. төлке...-ы; *лисий мех* — төлке мехы. ◇ **Лисий хвост** *бот.* — к. лисохвост.

**ЛИСИРОВА'ТЬ** I *сов.* и *несов. спец.*— ялтырату, шомартып ялтырату.

**ЛИСИРОВА'ТЬ** II *сов* и *несов.*— к. лессировать.

**ЛИСИРОВА'ТЬСЯ** *сов.* и *несов. страд.*— ялтыратылу, шомартып ялтыратылу.

**ЛИСИ'ТЬ** *несов. простореч.*— төлкеләнү, ялагайлану, юмакайлану.

**ЛИСИ'ЦА** *ж.*— 1. *зоол.* төлке; 2. *разг.* (*лисий мех*) төлке мехы.

**ЛИСИ'ЧКА** — 1. к. лисица; 2. (*гриб*) әтәч гөмбәсе.

**ЛИСОВА'ТЬ** *несов. спец.*— к. лисировать I.

**ЛИСОВЩИ'К** *м. спец.*— лисовщик, шомартучы, ялтыратучы эшче; *лисовщики гладят, скоблят бумагу* — лисовщиклар кәгазьне тигезлиләр, кырэлар.

**ЛИ'СОНЬКА** *ж. ласк. нар.-поэт.*—к. лиса.

**ЛИСОХВО'СТ** *м. бот.*— төлке койрык (үлән).

**ЛИСТ** *м.*— 1. *бот.* (*мн.* листья) яфрак; *дубовый лист* — имән яфрагы; 2. *только ед. собир.* яфраклар; *вянет лист, проходит лето* — яфраклар корый, җәй үтә; 3. (*мн.* листы) табак; *один лист бумаги* — бер табак кәгазь; *лист железа* — бер табак калай; *книга в десять листов* — ун табаклы китап. ◇ **Похвальный лист** — мактау кәгазе. **Исполнительный лист** — башкару кәгазе, исполнительный лист (суд яки учреждениенең карарын тормышка ашыруга хокук бирә торган таныклык). **Опросный лист** *офиц.*— к. анкета. **С листа** (играть, петь) — алдан хәзерлексез, нотадан карап (уйнау, җырлау).

**ЛИСТА'Ж** *м.* — листаж (китап ахырында күрсәтелгән басма табаклар санын тираж санына тапкырлаудан килеп чыккан сан — басма табак-оттисклар саны).

**ЛИСТА'ТЬ** *несов. разг.*— актару (китап битләрен).

**ЛИСТВА'** *ж. мн.* нет, *собир.*— яфраклар, яфрак.

**ЛИ'СТВЕННИЦА** *ж. бот.*— карагай.

**ЛИ'СТВЕННИЧНЫЙ** —карагай...-ы; *лиственничная ветка* — карагай ботагы.

**ЛИ'СТВЕННЫЙ** — 1. яфраклы; *лиственное дерево* — яфраклы агач; 2. яфраклы

агачлар...-ы; *лиственный лес* — яфраклы агачлар урманы.

**ЛИ'СТИК** *м. уменьш. разг.*— кечкенә яфрак.

**ЛИСТОВА'ТЬ** *несов. разг.*— к. листать.

**ЛИСТО'ВКА** *ж. разг.*— листовка (күбесенчә политик эчтәлекле кечкенә брошюра яки бер бит кәгазь).

**ЛИСТОВО'Й** — 1. яфрак...; *листовой табак* — яфрак тәмәке; 2. табаклы; *листовое железо* — табаклы калай.

**ЛИСТО'К** *м.*— 1. яфрак; *дубовый листок* — имән яфрагы; 2. бер бит кәгазь; *вырвать листок из тетради* — дәфтәрдән бер бит кәгазь ертып алу; 3. листок; *больничный листок* — больничный листок.

**ЛИСТОНО'С** *м. зоол.*— яфраккапат (яркапатның бер төре).

**ЛИСТООБРА'ЗНЫЙ** *книж.*— яфраксыман.

**ЛИСТОПА'Д** *м. мн.* нет — 1. яфрак коелу; 2. *(время опадания листьев)* яфрак коелу вакыты.

**ЛИСТОРЕ'З** *м. спец.*— калай кисүче (эшче).

**ЛИТА'ВРА** *ж. муз.*— литавра (музыка коралы).

**ЛИТАВРИ'СТ** *м. муз.*— литаврада уйнаучы (музыкант).

**ЛИТВИ'Н** *м.*, **ЛИТВИ'НКА** *ж. устар.*— литвалы.

**ЛИТЕ'ЙНАЯ** *в знач. сущ.* — кою эшләре мастерское, коеп ясау мастерское.

**ЛИТЕ'ЙНЫЙ** — (металл) кою...-ы; *литейный завод* — (металл) кою заводы; *литейное дело* —(металл) кою эше.

**ЛИТЕ'ЙЩИК** *м. спец.*— литейщик, коючы.

**ЛИ'ТЕР** *м. разг.*— к. литера 2б.

**ЛИ'ТЕРА** *ж.*— 1. *устар. канц.* *(буква)* хәреф; 2. литер (а. типографиядә кулланыла торган металл хәреф; б. тимер юлда йөргәндә льгота белән файдалану өчен бирелә торган таныклык).

**ЛИТЕРА'ЛЬНЫЙ** *книж.*— к. буквальный.

**ЛИТЕРА'ТОР** *м.*—язучы, әдип, әдәбиятчы.

**ЛИТЕРА'ТОРСТВО** *ср. мн.* нет, *книж.*— язучылык.

**ЛИТЕРА'ТОРСТВОВАТЬ** *несов. книж.*— язучы булу, язучылык эше белән шөгыльләнү.

**ЛИТЕРА'ТОРША** *ж. разг.*— к. литератор.

**ЛИТЕРАТУ'РА** *ж.* — әдәбият.

**ЛИТЕРАТУ'РНО** *нареч.*— әдәби, әдәби телдә; *литературно выражаться* — әдәби телдә сөйләү.

**ЛИТЕРАТУ'РНОСТЬ** *ж. мн.* нет — әдәбилек.

**ЛИТЕРАТУ'РНЫЙ** — 1. әдәби; *литературное произведение* — әдәби әсәр; 2. әдәбият...-ы; *литературный кружок* — әдәбият түгәрәге.

**ЛИТЕРАТУРОВЕ'Д** *м.*— әдәбиятчы, әдәбият белгече.

**ЛИТЕРАТУРОВЕ'ДЕНИЕ** *ср. мн.* нет — әдәбият белеме (әдәбият тарихы һәм теориясе турындагы фәннәр).

**ЛИТЕРАТУРОВЕ'ДНЫЙ** *книж.* — әдәбият белеме...-ы; *литературоведные науки* — әдәбият белеме фәннәре.

**ЛИТЕРАТУРОВЕ'ДЧЕСКИЙ** *книж.*— к. литературоведный.

**ЛИТЕРАТУ'РЩИНА** *ж. мн.* нет, *неодобр.*— литературщина, ясалма, күперенке, ялган әдәбилек.

**ЛИ'ТЕРНЫЙ** *спец.*— 1. хәреф...-ы; *литерный знак* — хәреф билгесе; 2. литерлы (хәреф белән билгеләнгән); *литерная ложа* — литерлы ложа (театрда).

**ЛИТЕРОВА'ТЬ** *сов. несов. спец.*— литерлау, литерлап чыгу (бәясенең дәрәҗәсен тиешле хәреф белән, мәсәлән, а, б, в хәрефләре белән, күрсәтеп, берәр нәрсәгә бәя бирү).

**ЛИ'ТИЙ** *м. мн.* нет— литий (химик элемент, көмешсыман ак, йомшак һәм җиңел металл).

**ЛИ'ТКА** *ж. спец.*— коелма (эретеп калыпка коелган металл кисәге).

**ЛИТМОНТА'Ж** *м.*— әдәби монтаж.

**ЛИТО'ВСКИЙ** — 1. литвалылар...-ы; *литовский язык*— литвалылар теле; 2. Литва...-ы; *Литовское княжество* — Литва кенәзлеге (электә).

**ЛИТО'ВЦЫ** *мн.*— литвалылар, Литва халкы.

**ЛИТО'ГРАФ** — литограф (литография эше мастеры).

**ЛИТОГРАФИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.*— литография юлы белән басу, ташка басу.

**ЛИТОГРАФИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. страд.*— литография юлы белән басылу, ташка басылу.

**ЛИТОГРАФИ'ЧЕСКИЙ** — к. литографский.

**ЛИТОГРА'ФИЯ** *ж.*— литография, таш басма (1. язуны яки рәсемне элек ташка төшереп, аннан соң кәгазьгә төшерү ысулы; 2. шундый ысул ярдәмендә басу мастерское; 3. шундый ысул ярдәмендә төшерелгән рәсем).

**ЛИТОГРА'ФСКИЙ** — литография...-ы; *литографский камень* — литография ташы.

**ЛИТО'Й** — коелган, эретеп коелган, коеп ясалган; *литой мяч* — коеп ясалган туп; *литая сталь* — эретеп коелган корыч.

**ЛИТР** *м.*— литр (1. сыекчалар үлчәү берәмлеге; 2. к. литровка).

**ЛИТРО'ВКА** *ж. разг.*— бер литрлык савыт, бер литр сыешлы савыт.

**ЛИТРО'ВЫЙ** — бер литрлы; *литровая бутылка* — бер литрлы шешә.

[литровый] — ...литрлы; *двухлитровый*— ике литрлы.

**ЛИТЬ** *несов.*— 1. *(заставлять течь)* агызу, түгү; салу; 2. *тех.* кою; 3. агып тору, агу; кою; *вода льёт из крана* — су краннан ага (агып тора); *дождь льёт* — яңгыр коя; 4. *перен. книж. поэт.* *(о свете, аромате и т. д.)* чәчү, тарату. ◇ **Лить слёзы** *книж.*— яшь түгү. **Лить масло в огонь** *перен.*— уткә керосин сибү. **Лить**

пули *перен.*— борчак ату, алдау, ялганлау. Лить кровь *книж.*— кан кою (үтерү).

**ЛИТЬЁ** *ср. мн.* нет, *тех.*— 1. кою, эретеп кою; 2. *собир.* (*литые вещи*) коелма, коеп ясалган әйберләр.

**ЛИ'ТЬСЯ** *несов.*— 1. (*течь струёю*) сиптереп агу; 2. *перен. книж. поэт.* (*распространяться в воздухе*) таралу; 3. *перен. книж. поэт.* яңгырау; *песни льются* — җырлар яңгырый; 4. (*о свете*) төшү, керү; сибелү, чәчелү; 5. *страд.* агызылу; коелу.

**ЛИФ** *м.*— лиф (хатын-кызлар бельёсының бер өлеше).

**ЛИФТ** *м.*— лифт (күп катлы биналарда кешеләрне менгерү һәм төшерү машинасы).

**ЛИФТЁР** *м. спец.*— лифтёр (лифтта эшләүче).

**ЛИ'ФЧИК** *м. разг.*— лифчик (балалар һәм хатын-кызлар бельёсының бер өлеше).

**ЛИХА'Ч** *м.*— 1. *нар.-поэт.* (*удалой*) җитез, җилле, булдыклы, кыю; 2. лихач (а. *неодобр.* үзенең батырлыгын, җитезлеген күрсәтер өчен, зыянлы, хәтта җинаятьле эшләр эшләүче кеше; б. *устар.* яхшы йөгерек атлы һәм зиннәтле экипажлы извозчик; в. *устар.* зиннәтле экипаж).

**ЛИХА'ЧЕСТВО** *ср. мн.* нет, *неодобр.*— лихачлык (шофёрның егетлек күрсәтәм дигән булып юл йөрү кагыйдәләрен бозуы).

**ЛИХВА'**, реже **ЛИ'ХВА** *ж. мн.* нет, *устар. обл.*— файда, табыш, процент (1. бурычка бирелгән капиталдан алына торган файда; 2. гомумән чамадан тыш зур файда). ◇ С лихвой *разг.*— артыгы белән.

**ЛИ'ХВЕННЫЙ** *устар.* и *обл.*— бик зур, чамадан тыш зур; *лихвенные проценты* — чамадан тыш зур процентлар.

**ЛИ'ХО** I *ср. мн.* нет, *обл. нар.-поэт.*— явызлык, яманлык. ◇ Поминать лихом *разг.*— начар сүз белән искә алу (кемне дә булса).

**ЛИ'ХО** II *нареч.*— шәп, җилле; егетләрчә, җитез, кыю.

**ЛИХОДЕ'Й** *м.*, **ЛИХОДЕ'ЙКА** *ж. устар. нар.-поэт.*— явыз (кеше), усал (кеше).

**ЛИХОДЕ'ЙСКИЙ** *устар. нар.-поэт.*— явыз, усал.

**ЛИХОДЕ'ЙСТВО** *ср. устар.*— явызлык, усаллык.

**ЛИХОИ'МЕЦ** *м. книж. устар.*— взятка алучы, ришвәтче.

**ЛИХОИ'МСТВО** *ср. мн.* нет, *книж. устар.*— взятка алу, взятка алу гадәте.

**ЛИХО'Й** I *нар.-поэт. обл.* – 1. (*злой, недобрый*) явыз, яман; 2. (*тягостный, губительный*) авыр, һәлакәтле. ◇ Лиха беда начало (начать) *простореч.*— бер башлап җибәрүе генә кыен.

**ЛИХО'Й** II *разг.*— 1. җилле; җитез, булдыклы; кыю, чая, тәвәккәл; 2. (*щегольской*) купшы, кәяз.

**ЛИХОЛЕ'ТЬЕ** *ср. книж. устар.*— авыр еллар (төрле чуалышлар, тынычсызлыклар, авырлыклар һ. б. чоры).

**ЛИХОРА'ДИТЬ** *несов.*— өшетү, бизгәк тоту, калтырату; *к вечеру его стало лихорадить* — кичкә таба аны бизгәк тота башлады (калтырата башлады, өшетә башлады).

**ЛИХОРА'ДКА** *ж.*— 1. (*болезнь*) бизгәк; 2. *перен. разг.* (*сильное волнение*) кайгы, каты борчылу, күңел тынычсызлыгы.

**ЛИХОРА'ДОЧНЫЙ** — 1. бизгәк белән...; *лихорадочный больной* — бизгәк белән авыручы; 2. бизгәк тотканда була торган; *лихорадочный бред* — бизгәк тотканда була торган саташу; 3. ярсулы; *лихорадочное волнение* — ярсулы борчылу ◇ Лихорадочные приготовления — ашыгыч хәзерләнүләр, шашынулы хәзерләнүләр.

**ЛИ'ХОСТЬ** *ж. мн.* нет, *разг.*— 1. осталык; җитезлек, булдыклылык; кыюлык, чаялык, тәвәккәллек; 2. купшылык, кәязлек.

**ЛИ'ХТЕР** *м. мор.*— лихтер (яссы төпле, җилкәнле кечкенә судно).

**ЛИЦЕВА'ТЬ** *несов. спец.*— 1. (*облицовывать*) тышлау; 2. (*перелицовывать*) әйләндереп тегү, әйләндерү (тискәре ягын әйләндереп тегү).

**ЛИЦЕВО'Й** — 1. бит...-ы; *лицевые мускулы* — бит мускуллары; 2. тышкы, өске; уң; *лицевая сторона материи* — тукыманың уң ягы (өске ягы); *лицевая сторона рукописи* — кульязманың өске ягы; 3. алгы; *лицевая сторона дома* — өйнең алгы ягы (фасады); 4. рәсемле, бизәкле; *лицевая рукопись* — рәсемле кульязма; *лицевой свод* — бизәкле гөмбәз. ◇ Лицевой счёт *бухг.*— лицевой счёт (билгеле бер кеше исеменә ачылган счёт).

**ЛИЦЕДЕ'Й** *м.*, **ЛИЦЕДЕ'ЙКА** *ж. старин.*— 1. актёр; 2. *перен.* (*притворщик*) битлек кигән, икейөзле, мөнафикъ.

**ЛИЦЕДЕ'ЙСТВО** *ср. старин.*— 1. *только ед.* актёрлык; 2. спектакль, тамаша; 3. *только ед. перен.* икейөзлелек, мөнафикълык.

**ЛИЦЕДЕ'ЙСТВОВАТЬ** *несов. старин.*— 1. уйнау (сәхнәдә); 2. *перен.* (*притворяться*) икейөзләләнү, мөнафикълану.

**ЛИЦЕЗРЕ'ТЬ** *несов. книж. ирон.*— үз күзе белән күрү.

**ЛИЦЕИ'СТ** *м. дореол. загр.*— лицеист (лицейда укучы, лицейда тәрбияләнүче).

**ЛИЦЕ'Й** *м.*— лицей (1. *истор.* элекке Россиядә — өстен сыйныф балалары өчен булган урта яки югары юридик мәктәп; 2. Франциядә — урта мәктәп).

**ЛИЦЕ'ЙСКИЙ** — лицей...-ы; лицейда (укыганда) язылган; лицейдагы; *лицейские товарищи* — лицейдагы иптәшләр; *лицейские стихи* — лицейда (укыганда) язылган шигырьләр.

**ЛИЦЕМЕ'Р** *м.* — икейөзле, мөнафикъ, эчкерле (кеше).

**ЛИЦЕМЕ'РИЕ** *ср. мн.* нет — икейөзлелек, мөнафикълык, эчкерлелек.

**ЛИЦЕМЕ'РИТЬ** *несов.* — икейөзләләнү, мөнафикълану.

**ЛИЦЕМЕ'РКА** *ж.*— к. лицемер.

**ЛИЦЕМЕ'РНЫЙ** — икейөзле, мөнафикъ, эчкерле; мөнафикъларча...; *лицемерная улыбка* — мөнафикъларча елмаю.

**ЛИЦЕНЗИО'ННЫЙ** *экон.* — 1. лицензия...-ы; *лицензионная система* — лицензия системасы; 2. лицензияләр бирә торган; *лицензионные органы* — лицензияләр бирә торган органнар.

**ЛИЦЕ'НЗИЯ** *ж. экон.* — лицензия (1. пошлинасыз яки льгота белән чит илләргә товар чыгару яки чит илләрдән товар кертү өчен рөхсәт; 2. шул рөхсәтне раслый торган документ; 3. гомумән бирәр нәрсәдән льгота белән яки акчасыз файдалану хокукы).

**ЛИЦЕПРИЯ'ТИЕ** *ср. мн.* нет, *книж. устар.* — яклаулы мөнәсәбәт, яклау.

**ЛИЦЕПРИЯ'ТНЫЙ** *книж. устар.* — яклауга нигезләнгән, яклаулы.

**ЛИЦЕПРИЯ'ТСТВОВАТЬ** *несов. книж. устар.* — бер яклы булу, яклау, яклаулы мөнәсәбәттә булу.

**ЛИЦО'** *ср.* — 1. бит, йөз, чырай; *мускулы лица* — бит мускуллары; *с румяным лицом* — алсу йөзле; *весёлое лицо* — ачык чырай; 2. *(наружная, верхняя, передняя сторона ч.-л.)* тышкы як, өске як; алгы як; 3. кеше; *отдельные лица* — аерым кешеләр; *известное лицо* — билгеле бер кеше; 4. *грам.* зат; *третье лицо* — өченче зат. ◇ **От лица** *книж.* — исеменнән. **Пред лицом** *книж.* — каршында, алдында. **Лицом к лицу** — йөзгә-йөз, кара-каршы. **В лице** *книж.* — йөзендә. **На одно лицо** *разг.* — бертөсле, бер-берсенә охшаган. **Не взирая на лица** *книж.* — кемнең кем булуына карамастан. **Показывать товар лицом** — яхшы яктан күрсәтү, отышлы яктан күрсәтү. **С лица не воду пить** *простореч.* — төсне табакка куймыйлар. **В лицо (говорить)** — йөзенә бәреп әйтү. **На лицо** *простореч.* — йөзенә карагайда. **Смотреть в лицо** — ... каршында тору. **Знать в лицо** — тану. **На нём лица нет** — чырае юк, чырае киткән, чырае агарган. **Измениться (перемениться) в лице** — төсе китү (куркудан, дулкынланудан һ. б.). **На лице написано** — к. написать. **Лицом в грязь не ударить** *разг.* — к. грязь. **К лицу** — килешә; *эта шляпа вам не к лицу* — бу эшләпә сезгә килешми; *мне не к лицу заниматься такими пустяками* — андый юкбар нәрсәләр белән мавыгу миңа килешми. **Стереть с лица земли** *книж. ритор.* — юк итү, җир йөзеннән себереп ташлау. **Действующее лицо** — катнашучы. **Физическое лицо** *право* — физик шәхес (җәмгыятьнең тулы хокуклы члены). **Юридическое лицо** *право* — юридик шәхес (закон буенча хокук субъекты, хокуклары да, бурычлары да, йөкләмәләре дә булган учреждение яки коллектив). **Лицом (повернуться)** *перен. книж.* — игътибарны юнәлдерү. **Спасти (сохранить) своё лицо** *книж.* — абруйны саклау.

**ЛИ'ЧИКО** *ср. разг.* — к. лицо 1.

**ЛИЧИ'НА** *ж.* — 1. *устар.* маска, битлек; 2. *презрит. (лицо, обличье)* йөз, кыяфәт; 3. *тех.* йозак йөзлеге (эчке йозак турысына тыштан куелган калай яки металл пластинка).

**ЛИЧИ'НКА** I *ж. зоол.* — корт, личинка.

**ЛИЧИ'НКА** II *ж.* — личинка (мылтыкта).

**ЛИЧИ'НКА** III *ж. тех.* — к. личина 3.

**ЛИ'ЧНО** *нареч. книж. офиц.* — үзе; *должен лично расписаться* — үзе кул куярга тиеш; *лично я ничего не имею против* — мин үзем һич тә каршы түгелмен.

**ЛИЧНО'Й** *спец.* — бит...-ы; биткә сөртә торган; *личное мыло* — бит сабыны; *личной крем* — биткә сөртә торган крем.

**ЛИ'ЧНОСТЬ** *ж.* — 1. *только ед.* кеше, шәхес; 2. *книж.* йөз; *литературная личность Гоголя* — Гогольнең әдәби йөзе; 3. *простореч.* *(физиономия, лицо)* йөз. ◇ **Прошу без личностей** — аерым кешеләргә кагылмавыгызны үтенәм.

**ЛИ'ЧНЫЙ** — 1. шәхси; *личный интерес* — шәхси интерес; *личная собственность* — шәхси милек; 2. *книж.* үз; *требуется его личное участие* — үзенең катнашуы таләп ителә; *это моё личное дело* — бу минем үз эшем; 3. *грам.* зат...-ы; *личные местоимения* — зат алмашлыклары. ◇ **Личный состав** — эшләүчеләр составы, хезмәт итүчеләр составы (учреждениедә, предприятиедә, армиядә).

**ЛИША'Й** *м.* — 1. *мед.* тимрәү (авыру); 2. *бот.* лишай.

**ЛИША'ЙНИК** *м. бот.* — к. лишай 2.

**ЛИША'ЙНЫЙ** — 1. *мед.* тимрәү...-ы; *лишайные пятна* — тимрәү эзләре; 2. *бот.* лишай...-ы; *лишайные породы* — лишай токымнары.

**ЛИША'ТЬ** *несов.* — к. лишить.

**ЛИША'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. лишиться; 2. *страд.* мәхрүм ителү, ...-сыз калдырылу.

**ЛИ'ШЕК** *м. простореч.* — артык, калдык; *взять сколько нужно, а весь лишек отдать назад* — кирәк хәтле алырга да артыгын (калдыгын) кайтарып бирергә. ◇ **С лишком** *разг.* — артыгы белән.

**ЛИШЕ'НЕЦ** *м.* — хокуксыз кеше (хокуктан мәхрүм ителгән кеше).

**ЛИШЕ'НИЕ** *ср. книж.* — 1. *(действие)* к. лишить, лишиться; 2. *только мн.* *(нищета, недостаток)* мохтаҗлыклар, авырлыклар.

**ЛИШЕ'НКА** *ж.* — к. лишенец.

**ЛИШЁННЫЙ** — мәхрүм ителгән, ...-сыз калдырылган; ...-сыз калган; *лишённый помощи* — ярдәмсез калдырылган; ярдәмсез калган. ◇ **Лишённый крова** — урамда калган. **Не лишённый (не лишён)** — ...-ы булган; шактый гына; *событие, не лишённое известного значения* — билгеле бер әһәмияте булган вакыйга; *он не лишён ума* — ул шактый гына акыллы кеше. **Ваше замечание лишено всякого значения** — сезнең искәртүнең һичбер әһәмияте юк.

**ЛИШИ'ТЬ** *сов. книж.* — мәхрүм итү, ...-сыз калдыру; *лишить свободы* — иректән мәхрүм итү; *лишить помощи* — ярдәмсез калдыру. ◇ **Лишить жизни** — үтерү. **Лишить слова** — сүз бирмәү, сөйләргә бирмәү.

**ЛИШИ'ТЬСЯ** *сов. книж.* — ...-сыз калу, югалту; *лишиться сына* — улын югалту; улсыз калу; *лишиться помощи* — ярдәмсез калу.

**ЛИ'ШНИЙ** — 1. артык; *лишние деньги* — артык акча; 2. артык, кирәксез; *лишние вещи* — кирәксез әйберләр; *это совсем лишнее* — бу бөтенләй артык; 3. тагы; *накинуть лишних сто рублей* — тагы йөз сум өстәү; *хочется взглянуть лишний разок* — тагы бер тапкыр карыйсы килә. ◇ **С лишним** *разг.* — артык, артыграк, артыгы белән; *книга стоит три рубля с лишним* — китапның хакы өч сумнан артык. **Не лишне** *книж.* — артык булмас.

**ЛИШЬ** — 1. *нареч. ограничит.* гына, бары ... гына, тик ... гына; *нехватает лишь одного* — тик берәү генә житми; 2. *союз временной* ...-ган гына ... иде, ...-гач та, ...-ү белән; *лишь показалась станция, пассажиры стали суетиться* — станция күренү белән, пассажирлар ыгы-зыгы килә башлады. ◇ **Лишь только** — к. **лишь** 2.

**ЛОБ** *м.* — маңгай. ◇ **На лбу написано** *разг.* — к. **написать. Медный лоб** — к. **медный. Семи пядей во лбу** — бик акыллы. **Что в лоб, что по́ лбу** *просторeч.* — барыбер. **Лоб забрить** — к. **забрить. Пустить себе пулю в лоб** — үзен үзе атып үтерү, атылып үлү. **В лоб** *воен. спец.* — туп-туры, кара-каршы. **Зарубить на лбу** — к. **зарубить**.

**ЛОБА'Н** *м.* — 1. *разг. фам.* киң маңгайлы (кеше); 2. *зоол.* лобан (балыкның бер төре).

**ЛОБА'НЧИК** *м. просторeч. устар.* — лобанчик (алтын акча).

**ЛОБА'СТЫЙ** *разг.* — киң маңгайлы.

**ЛОБЗА'НИЕ** *ср. книж. поэт. устар.* — үбү. ◇ **Иудино лобзание** *книж. ритор.* — ичейөзлеләнеп үбү.

**ЛОБЗА'ТЬ** *несов. книж. поэт. устар.* — үбү.

**ЛОБЗА'ТЬСЯ** *несов. устар.* — үбешү.

**ЛО'БЗИК** *м. спец.* — лобзик (махсус рамкага куелган бик нечкә пычкы).

**ЛО'БИК** *м.* — 1. *разг.* к. **лоб**; 2. *спец.* к. **лобок** 2.

**ЛОБКО'ВЫЙ** — 1. *анат.* касык ...-ы; *лобковая кость* — касык сөяге; 2. *спец.* маңгай тиресеннән эшләнгән; маңгай тиресеннән хәзерләнгән; *лобковая кожа* — маңгай тиресеннән эшләнгән күн.

**ЛО'БНЫЙ** *анат.* — маңгай ...-ы; *лобная кость* — маңгай сөяге. ◇ **Лобное место** *истор.* — 1. борын заманда патша боерыкларын игълан итү һәм халыкка речьләр сөйләү өчен эшләнгән махсус урын; 2. җәзалау урыны.

**ЛОБОВО'Й** *воен. спец.* — 1. каршы; *лобовой ветер* — каршы жил; 2. алгы; *лобовые фонари трамвайных вагонов* — трамвай вагоннарының алгы фонарьлары.

**ЛОБОГРЕ'ЙКА** *ж. с.-х.* — лобогрейка, ургыч (машина).

**ЛОБО'К** *м.* — 1. *анат.* касык сөяге; 2. *спец.* хайваннарның маңгай тиресе.

**ЛОБОТРЯ'С** *м. просторeч. бран.* — к. **бездельник**.

**ЛОБЫЗА'ТЬ** *несов. устар., теперь разг. ирон.* — к. **лобзать**.

**ЛОВ** *м.* — 1. к. **ловля**; 2. к. **улов**.

**ЛОВЕЛА'С** *м. разг. шутл.* — ловелас (хатын-кызлар артыннан йөрүче, хатын-кызларны алдаучы).

**ЛОВЕЛА'СНИЧАТЬ** *несов. разг. неодобр.* — ловеласларча кылану, ловеласлану.

**ЛОВЕ'Ц** *м.* — 1. *спец.* (*рыболов*) балыкчы, балык тотучы; 2. *устар.* (*охотник*) аучы, сунарчы.

**ЛОВЕ'ЦКИЙ** *спец.* — балыкчылар...-ы; аучылар...-ы; *ловецкие артели* — балыкчылар артеле, аучылар артеле.

**ЛОВИ'ТЬ** *несов.* — тоту; аулау; *ловить рыбу* — балык тоту; *ловить зверя* — җәнлек аулау. ◇ **Ловить женихов** *просторeч. фам.* — кияү аулау (үзенә, кызына һ. б. кияү табарга тырышу). **Ловить взгляд** — күз карашын тотып алырга тырышу, күзенә чагылырга тырышу. **Ловить каждое слово** — һәрбер сүзен отып алырга тырышу. **Ловить момент** — моментны туры китерү, моментны ычкындырмау, уңай моменттан файдалану. **Ловить на лжи** — ялганын тоту. **В мутной воде рыбу ловить** — болганчык суда балык тоту.

**ЛОВИ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — тотылу; аулану.

**ЛОВКА'Ч** *м.*, **ЛОВКА'ЧКА** *ж. разг. фам. неодобр.* — житез, булдыклы, оста, өлгер, үзенә кирәкне рәтли белүче.

**ЛО'ВКИЙ** — 1. оста; *ловкий игрок* — оста уйнаучы; *ловкий прыжок* — оста сикереш; 2. *разг.* житез, өлгер; булдыклы, булган; оста; *ловкий человек* — житез (булдыклы) кеше; *ловкий плут* — оста алдакчы; 3. *разг.* уңайлы, иплe; *ловкое седло* — уңайлы ияр.

**ЛО'ВКОСТЬ** *ж. мн.* нет — осталык; булдыклылык, житезлек.

**ЛО'ВЛЯ** *ж.* — 1. *только ед.* (*действие*) к. **ловить**; 2. балык тота торган урын.

**ЛОВУ'ШКА** *ж.* — тозак.

**ЛО'ВЧИЙ** I — 1. ау...-ы; *ловчие собаки* — ау этләре; 2. саклау...-ы; *ловчие рвы* — саклау канаулары (җимеш бакчаларын, чәчүлекләрне үрмәләүче зарарлы бөҗәкләрдән саклау өчен казылган канаулар).

**ЛО'ВЧИЙ** II *м. истор.* — ловчий (алпавытларда, боярларда аучылык, балык тоту эшләре белән идарә итүче кеше).

**ЛОВЧИ'ЛА** *м. и ж. просторeч.* — эшен оста йөртүче.

**ЛОВЧИ'ТЬ** *несов. просторeч.* — эшне оста йөртү.

**ЛОГ** *м.* — 1. *обл.* киң чокыр; 2. *обл.* ташландык басу; 3. *спец.* кирпеч кабыргасы (кирпечнең тар, озынча кырые).

**ЛОГАРИ'ФМ** *м. мат.* — логарифм.

**ЛОГАРИФМИ'ЧЕСКИЙ** *мат.* — логарифмик; *логарифмическая таблица* — логарифмик таблица.

**ЛО'ГИК** *м.* — логик, логика белгече.

**ЛО'ГИКА** *ж.* — логика (1. фикер йөртү формалары һәм аның законнары турындагы фән; 2. эштә, фикер йөртүдә эчке закончалылык, акылга ятышлылык).

**ЛОГИ'ЧЕСКИЙ** *книж.* — логик, логикага нигезләнгән; *логический вывод* — логик нәтиҗә.

**ЛОГИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет — логикага ингезләнгәнлек; закончалылык, акылга ятышлылык.

**ЛОГИ'ЧНЫЙ** — закончалы, акылга ятышлы, эзлекле; логикалы; *логичное рассуждение* — эзлекле фикер йөртү.

**ЛО'ГОВИЩЕ** *ср.* — оя, өн.

**ЛО'ГОВО** *ср.* — к. логовище.

**ЛОГОГРИ'Ф** *м.* — логогриф (башваткычларның бер төре).

**ЛОГОПА'Т** *м. мед.* — логопат (сакау, тыңкыш һ. б.).

**ЛОГОПА'ТИЯ** *ж. мн.* нет — логопатия (сакаулык, тотлыгып сөйләү, тыңкышлык һ. б.).

**ЛОГОПЕ'Д** *м. спец.* — логопед, логопедия белгече.

**ЛОГОПЕДИ'ЧЕСКИЙ** *спец.* — логопедия...-ы; *логопедический институт* — логопедия институты.

**ЛОГОПЕ'ДИЯ** *ж. мн.* нет — логопедия (сөйләү җитешсезлекләрен бетерү).

**ЛО'ДКА** *ж.* — көймә, каек.

**ЛО'ДОЧКА** *ж. разг.* — кечкенә көймә, кечкенә каек.

**ЛО'ДОЧНИК** *м.* — көймәче (көймәләр тотучы яки көймәдә кешеләр йөртүче).

**ЛО'ДОЧНЫЙ** — көймә...-ы, көймәләр...ы, көймәдә...; *лодочные гонки* — көймәдә узышу; *лодочная станция* — көймәләр станциясе; *лодочная цепь* — көймә чылбыры.

**ЛОДЧО'НКА** *ж. разг.* — көймә кисәге, начар көймә.

**ЛОДЫ'ГА** *ж. обл. устар.* — к. лодыжка.

**ЛОДЫ'ЖКА** *ж.* — тубык сөяге.

**ЛО'ДЫРНИЧАТЬ** *несов. простореч. пренебр.* — эшсез йөрү, кыл кыймылдатмау, ялкаулану, ялкаулыкка бирелү, ялкаулыкка сабышу.

**ЛО'ДЫРЬ** *м. простореч. пренебр.* — эшлексез, ялкау. ◇ **Гонять лодыря** — к. гонять.

**ЛО'ЖА** *ж.* — 1. ложа (а. тамаша яки җыелыш залларында бүлеп ясалган берничә кешелек урын; б. *истор.* масоннар оешмасының бүлеге); 2. *спец.* к. ложе 3.

**ЛОЖБИ'НА** *ж.* — уйсулык, уйсу җир.

**ЛОЖБИ'НКА** *ж.* — 1. кечкенә уйсулык, уйсу җир; 2. *спец.* кечкенә улак.

**ЛО'ЖБИЩЕ** *ср. спец.* — туплавык, яткылык (җәнлекләр җыелып ята торган урын).

**ЛО'ЖЕ** *ср.* — 1. *книж. устар. (постель)* урын, түшәк; түшәк-ястык; 2. *книж. (русло реки)* елга юлы; 3. *спец. (у ружья)* ложе.

**ЛОЖЕМЕ'НТ** *м. воен. устар.* — окоп.

**ЛО'ЖЕЧКА** I *ж.* — кечкенә кашык.

**ЛО'ЖЕЧКА** II *ж. устар.* — күкрәк авызы; *боль под ложечкой* — күкрәк авызы авырта; *под ложечкой щемит* — күкрәк авызым чәнчешә.

**ЛО'ЖЕЧНИК** *м. спец.* — 1. к. ложкарь; 2. кашыклар шакылдатып уйнаучы.

**ЛО'ЖЕЧНЫЙ** *спец.* — кашык...-ы, кашыклар...-ы; *ложечное производство* — кашык производствосы.

**ЛОЖИ'ТЬ** *несов. простореч. обл.* — кую, салу.

**ЛОЖИ'ТЬСЯ** — к. лечь 1, 2, 4, 5, 6.

**ЛО'ЖКА** *ж.* — 1. кашык; *столовая ложка* — аш кашыгы; *чайная ложка* — бал кашыгы, калак. 2. *только мн. муз.* кашыклар (кашыксыман гади музыкаль инструмент). ◇ **Через час по чайной ложке** *перен.* — аз-аз, азлап; акрын-акрын, акрынлап; теләмичә.

**ЛОЖКА'РНЫЙ** *спец.* — кашыкчы...-ы, кашыкчылар...-ы; *ложкарное ремесло* — кашыкчы һөнәре.

**ЛОЖКА'РЬ** *м. спец.* — кашыкчы, кашыклар ясаучы.

**ЛОЖНОКЛАССИЦИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *лит.* — ялган классицизм (XVI гасырда Франциядә барлыкка килгән әдәби агым).

**ЛОЖНОКЛАССИ'ЧЕСКИЙ** *лит.* — ялган классицизм...-ы, ялган классик; *ложноклассическое направление* — ялган классицизм агымы; *ложноклассическая трагедия* — ялган классик трагедия.

**ЛО'ЖНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — 1. ялгышлык; 2. ясалмалык, ялганлык.

**ЛО'ЖНЫЙ** — 1. ялган; *ложные слухи* — ялган хәбәрләр; *ложное учение* — ялган тәгълимат; 2. ялган, ясалма, урынсыз, тышкы; *ложная скромность* — ялган тыйнаклык, урынсыз тыйнаклык.

**ЛОЖО'К** *м.* — 1. *архит.* озынча улак (колонналарда); 2. *спец.* к. лог 3; 3. *обл.* к. лог 1.

**ЛОЖЬ** *ж. мн.* нет — ялган.

**ЛОЗА'** *ж.* — 1. *(стебель)* озын сыгылма ботак; 2. *бот. (кустарник)* таллык; 3. *устар. (розга)* чыбык, талчыбык.

**ЛОЗИ'НА** *ж. мн.* нет, *обл.* — тал чыбыгы.

**ЛОЗНИ'К** *м. обл.*, **ЛОЗНЯ'К** *м. мн.* нет — таллык, әрәмә.

**ЛО'ЗУНГ** *м.* — 1. лозунг; 2. *воен. устар.* отзыв 4.

**ЛО'ЗУНГОВЫЙ** *книж.* — лозунг...-ы, лозунгка хас; *лозунговый стиль* — лозунг стиле, лозунгка хас стиль.

**ЛОЙЯ'ЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — к. лояльность.

**ЛОЙЯ'ЛЬНЫЙ** *книж.* — к. лояльный.

**ЛОКАЛИЗА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *книж.* — к. локализовать, локализоваться.

**ЛОКАЛИЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. книж.* — к. локализовать.

**ЛОКАЛИЗИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. книж.* — к. локализоваться.

**ЛОКАЛИЗОВА'ТЬ** *сов.* и *несов. книж.* — 1. урынын анык билгеләү, билгеле урынга кую, урнаштыру; 2. локальләштерү, җәелдермәү, басу, чыккан урынында туктату; *локализовать эпидемию* — эпидемияне локальләштерү.

**ЛОКАЛИЗОВА'ТЬСЯ** *сов.* и *несов. книж.* — 1. *(сосредоточиться в определенном месте)* урнашу, туплану, локальләшү; 2. *страд.* локальләштерелү, туктатылу.

**ЛОКА'ЛЬНЫЙ** *книж. офиц.* — локаль, җирле (билгеле бер урынга хас).

**ЛОКА'УТ** *м. полит.* — локаут (эшчеләр-

не авыр шартларда эшләргә мәҗбүр итү һәм стачкаларга юл куймау максаты белән капиталистларның, завод-фабрикаларны ябып, эшчеләрне массовый рәвештә эштән чыгаруы).

**ЛОКАУТИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. полит.* — локаут игълан итү.

**ЛОКОМОБИ'ЛЬ** *м.* *тех.* — локомобиль (төрле машиналарны хәрәкәткә китерә торган күчмә пар двигателе).

**ЛОКОМОБИ'ЛЬЩИК** *м. спец.* — локомобильщик, локомобильдә эшләүче.

**ЛОКОМОТИ'В** *м.* — локомотив (1. *тех.* паровоз, тепловоз, электровоз; 2. *перен.* хәрәкәткә китерүче көч, хәрәкәтләндерүче көч, алга җибәрүче көч; *революция — локомотив истории* — революция — тарихның локомотивы).

**ЛО'КОН** *м.* — локон, бөтеркә (бөдрәләнеп торган чәчнең бер бөтеркәсе).

**ЛОКОТНИ'К** *м.* — култыкса (диван яки кресло култыксасы).

**ЛО'КОТЬ** *м.* — терсәк.

**ЛОКТЕВО'Й:** **локтевая кость** — терсәк сөяге: **локтевое сочленение** — терсәк.

**ЛОМ** *м.* — 1. лом; 2. *только ед. собир.* ватык, лом; *металлический лом* — металл ломы (металл ватыгы); 3. *просторец.* к. ломота.

**ЛОМА'КА** *м.* и *ж. просторец. неодобр.* — кыланчык, кыланучан кеше.

**ЛО'МАНЫЙ** — 1. ватык, ватылган, сынык, уалган; *ломаные вещи* — ватык әйберләр; 2. *перен. просторец. фам. неодобр.* кыланучан, кыланчык. ◇ **Говорить на ломаном языке** *перен.* — тел бозып сөйләү, тел ватып сөйләү. **Ломаная линия** *мат.* — сынык сызык.

**ЛОМА'ТЬ** *несов.* — 1. сындыру; *ветер ломает деревья* — җил агачларны сындыра; 2. *с.-х.* сындырып җыю; *ломать кукурузу* — кукурузаны сындырып җыю; 3. вату, бозу, яраксыз хәлгә китерү; *ломать машину* — машинаны вату; 4. *перен. книж.* вату, җимерү, юкка чыгару; *ломать старые порядки* — иске тәртипләрне җимерү; 5. *перен.* үзгәртү, бозу; *ломать свою жизнь* — үз тормышыңны бозу; 6. *перен. просторец.* сызлау, авырту; *меня всего ломает* — (минем) бөтен тәнем сызлый (авырта); 7. вату; *ломать лёд* — боз вату. ◇ **Ломать голову** — баш вату (кыен мәсьәләне ничек чишү турында уйлау). **Ломать шапку** (*перед кем-н.*) *разг.* — кемгә дә булса ярарга тырышып, баш ию. **Дурака ломать** *просторец.* — кылану, ахмаклык эшләү.

**ЛОМА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. ватылу, җимерелү; *лёд ломается* — боз ватыла; 2. сыну; *сучья ломаются* — ботаклар сына; 3. *разг.* кылану, назлану, боргалану-сыргалану. ◇ **У мальчика ломается голос** — малайның тавышы үзгәрә.

**ЛОМБА'РД** *м.* — ломбард (закладка әйбер алып, шуның өчен бурычка вакытлыча акча биреп тора торган учреждение).

**ЛОМБА'РДНЫЙ** — ломбард...-ы; *ломбардная квитанция* — ломбард квитанциясе.

**ЛО'МБЕРНЫЙ:** **ломберный стол** — ломбер өстәл, карта уены өстәле.

**ЛОМИ'ТЬ** *несов. разг.* — 1. сыгу, бөгү; *яблоки ломят сучья* — алмалар ботакларны бөгәләр; 2. *разг.* бәреп-ватып керү, җимереп керү; этешеп-төртешеп керү; *народ так и ломит* — халык этешеп-төртешеп керә дә керә; 3. *безл.* сызлау; *ломит ногу* — аягым сызлый. ◇ **Ветер так и ломит** — җил аяктан ега, агачларны бөгә.

**ЛОМИ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. (*гнуться от сильного напора*) сыгылу, бөгелү; 2. *разг.* (*лезть насильно*) ватып керү, җимереп керү.

**ЛО'МКИЙ** — (тиз) ватылучан, уалучан, (тиз) сынучан.

**ЛО'МКОСТЬ** *ж. мн.* нет — тиз ватылучанлык, уалучанлык, тиз сынучанлык.

**ЛОМОВИ'К** *м.* *разг.* — 1. ломовой (йөк ташучы); 2. *обл.* *спец.* (*тяжеловоз*) йөк аты.

**ЛОМОВО'Й** — 1. йөк...-ы; *ломовая лошадь* — йөк аты; 2. *в знач. сущ.* ломовой (йөк ташучы); 3. *обл.* авыр; *ломовая работа* — авыр эш; 4. *спец.* вату; *ломовой инструмент* — вату инструменты.

**ЛОМО'ТА** *ж. мн.* нет, *разг.* — сызлау, авырту, сөякләр сызлау (тәннең ватылып, сыкранып торуы).

**ЛО'МОТЬ** *м.* — телем, сынык.

**ЛО'МТИК** *м.* — кечкенә телем, кечкенә сынык.

**ЛО'НЖА** *ж. спец.* — 1. к. корда; 2. лонжа (акробатлык сәнгатенә өйрәткәндә кулланыла торган бау).

**ЛОНЖЕРО'Н** *м.* *авиац.* *тех.* — лонжерон (самолёт канатының бер өлеше).

**ЛО'ННЫЙ** *анат.*: **лонное сочленение** — касык тоташмасы; **лонный бугорок** — касык калыкмасы.

**ЛО'НО** *ср. мн.* нет, *книж. устар.* — кочак, куен; *на лоне матери* — әнисенең кочагында. ◇ **На лоне природы** *разг. шутл.* — ачык һавада, табигать кочагында.

**ЛОПАРИ'** *мн.* — лопарьлар, лопарь халкы (саами халкының элеккеге исеме).

**ЛОПА'РКА** *ж.* — лопарь хатын-кызы.

**ЛОПА'РСКИЙ** — лопарь...-ы, лопарьлар...-ы; *лопарьский язык* — лопарь теле.

**ЛО'ПАСТНЫЙ** *тех.* — калаклы; *лопастное колесо* — калаклы көпчәк (мәсәлән, пароход көпчәге).

**ЛО'ПАСТЬ** *ж.* — 1. калак (көрәкнең, ишкәкнең киң, яссы өлеше); 2. *мор. тех.* калак, канат (мәсәлән, пароход көпчәгенең суны ишә торган калагы).

**ЛОПА'ТА** *ж.* — көрәк. ◇ **Борода лопатой** *разг.* *фам.* — көрәк сакал. **Грести (загребать) деньги лопатой** *просторец.* — акчаны көрәп алу (күп акча алу).

**ЛОПА'ТКА** *ж.* — 1. кечкенә көрәк, калак; 2. (*плечевая кость*) калак сөяге; 3. *обл.* яссы кузак. ◇ **Во все лопатки (удирать, бежать, гнать)** *разг.* *фам.* — җан фәрманга (качу, йөгерү, куу). **Положить на обе лопатки** — 1) *спорт.* егу (көрәшкәндә җиңү); 2) *перен.* җиңү (тулысынча җиңү).

**ЛО'ПАТЬ I** *несов. простореч. вульг.* — бүсү, тыгыну (комсызланып ашау).

**ЛО'ПАТЬ II** *несов. обл.* — к. лопаться.

**ЛО'ПАТЬСЯ** *несов.* — к. лопнуть. ◇ Лопаться от жиру *разг. фам.* — симезлектән шартларга житү.

**ЛО'ПНУТЬ** *сов.* — 1. шартлау, чатнау, ярылу; *лопнул стакан* — стакан шартлады, чатнады; 2. өзелү; *струна лопнула* — кыл өзелде; 3. *перен.* бөлү; шартлау; *банк лопнул* — банк шартлады, бөлде (капиталистик илләрдә була торган хәл); 4. *перен. простореч. фам.* шартлау; *чуть не лопнул со злости* — ачуымнан шартлый яздым. ◇ **Терпение моё лопнуло** *разг.* — сабырлыгым бетте; чыдар хәлем калмады. **Лопни глаза мои** *вульг.* — күзем чыксын. **Хоть лопни** *простореч.* — шартласаң да. **Чтоб ты лопнул!** *простореч.* — башың беткере, дөмеккере, җәһәннәмгә киткере. **Всё дело лопнуло** — бөтен эш бозылды.

**ЛОПОТА'ТЬ** *несов. простореч.* — лыгырдау, күп сөйләү.

**ЛОПОУ'ХИЙ** *простореч. пренебр.* — 1. салпы колаклы; *лопоухий щенок* — салпы колаклы көчек; 2. *перен.* салпы колак, ахмак; ачык авыз.

**ЛОПУ'Х** *м.* — 1. *бот.* әрекмән; 2. әрекмән яфрагы.

**ЛОПУ'ШНИК** *м. обл.* — әрекмәнлек.

**МАССОВИ'К** *м.* — массовик (1. *полит.* турыдан-туры масса белән эш итүче, халык арасында эшләүче агитатор-пропагандист; 2. паркларда, бакча һәм клубларда күңел ачулар, уеннар оештыручы).

**МАССО'ВКА** *ж. разг.* — 1. кечкенә митинг; 2. массовка (күңел ачып кайту теләге белән күп кеше өчен оештырылган экскурсия).

**МА'ССОВОСТЬ** *ж. мн.* нет — киң таралу, киң җәелү; *массовость спорта* — спортның киң таралуы.

**МА'ССОВЫЙ** — 1. күп кеше катнашкан; *массовая экскурсия* — күп кеше катнашкан экскурсия; 2. күпләп; *массовое производство* — күпләп җитештерү; 3. киң масса өчен ...-ган; *массовая литература* — киң масса өчен чыгарылган әдәбият; *массовые зрелища* — киң масса өчен оештырылган тамашалар; 4. киң таралган, киң җәелгән, киң күләмдәге, массовый; *массовое движение сторонников мира* — тынычлык яклаучыларның массовый хәрәкәте. ◇ **Товары массового потребления** — киң куллану товарлары.

**МАСТА'К** *м просторен.* — мастер, оста, тәҗрибәле кеше, һөнәрле (кеше).

**МАСТА'ЧИТЬ** *несов. просторен. фам.* — эшләү, ясау, хәзерләп чыгару.

**МА'СТЕР** *м.* — 1. мастер (производствоның билгеле бер тармагын идарә итүче); 2. оста, мастер; *сапожный мастер* — итек остасы; *мастера современной литературы* — хәзерге әдәбият осталары (мастерлары); *мастер спорта* — спорт мастеры. ◇ **Дело мастера боится** — эш остадан курка. **Мастер на все руки** — бөтен эш кулыннан килә.

**МАСТЕРИ'ТЬ** *несов. разг.* — ясау, эмәлләү; *мальчик мастерит себе пароходик* — малай үзенә уенчык пароход ясый.

**МАСТЕРИ'ЦА** *ж.* — 1. мастерица (тегү яки эшләпә мастерскоенда эшләүче хатынкыз); 2. оста (хатын-кыз); *я не мастерица рассказывать* — мин сөйләргә оста түгел.

**МАСТЕРОВО'Й** *м. устар.* — мастеровой (фабрика яки завод эшчесе).

**МАСТЕРСКА'Я** *ж.* — мастерской, эш бүлмәсе (1. нинди дә булса производство өчен җайлаштырылган махсус бүлмә; *мастерская художника* — художникның эш бүлмәсе; 2. зур заводта яки фабрикада бер бүлек, цехның бер өлеше).

**МАСТЕРСКИ'** *нареч.* — мастерларча, оста итеп, үрнәк булырлык итеп.

**МА'СТЕРСКИЙ, МАСТЕРСКО'Й** — оста, яхшы, мастерларча, үрнәк булырлык; *мастерское исполнение* — оста башкарылыш.

**МАСТЕРСТВО'** *ср. мн.* нет — 1. һөнәр; *слесарное мастерство* — слесарьлык һөнәре; 2. осталык; мастерлык; *роман написан с большим мастерством* — роман зур осталык белән язылган.

**МАСТИ'КА** *ж.* — мастика (1. вак скульптура әйберләре ясаганда замазка итеп кулланыла торган куе масса; 2. паркет идәннәрне ышкып ялтырату өчен балавыздан һәм буяудан ясалган сыекча; 3. кайбер агачларның хуш исле сумаласы). ◇ **Мастиковое дерево** — мастика агачы (Урта диңгез буенда үсә һәм хуш исле сумала бирә торган кечкенә генә агач).

**МАСТИ'СТЫЙ** *спец.* — яхшы нәселле (ат турында); *мастистая лошадь* — яхшы нәселле ат.

**МАСТИ'ТЫЙ** *книж.* — хөрмәтле, күп хезмәт күрсәтеп хөрмәт казанган; олы яшьле; *маститый учёный* — күп хезмәт күрсәтеп хөрмәт казанган галим.

**МАСТИ'ЧНЫЙ** — мастикадан ясалган; *мастичные изделия* — мастикадан ясалган әйберләр.

**МАСТЬ** *ж.* — 1. хайван төсе (күбесенчә атларда); *гнедая масть* — туры (ат); 2. масть (уен картасында); *червонная масть* — черви масте. ◇ **Не к масти** *просторен.* — ярамый, иш түгел, туры килми.

**МАСШТА'Б** *м.* — 1. масштаб (картадагы, чертёждагы сызыклар озынлыгының картага, чертёжга төшерелгән урындагы сызыкларның чын озынлыгына мөнәсәбәте; мәсә-

лән, картадагы бер сантиметр озынлыгындагы сызыкның урынадагы 25 километрлы сызыкка туры килүе); 2. күләм; *в мировом масштабе* — дөнья күләмендә; *в маленьком масштабе* — кечкенә күләмдә.

**МАТ** I *м.*— 1. мат (шахмат уенында җиңелү); 2. *перен. простореч. шутл.* өметсез хәл, котылгысыз хәл, һәлакәт.

**МАТ** II *м.*— тупас җәймә, чипта (калдык-постыктан үрелгән).

**МАТ** III *м. мн.* нет, *спец.*— тоныклык, үтә күренмәү.

**МАТ** IV *м.*: **благим матом** (кричать, орать и т. д.) *простореч.* — бик ачы итеп, бөтен көче белән (кычкыру, акыру һ. б.).

**МАТАДО'Р** *м.*— матадор (1. Испаниядә үгез белән көрәштә төп сугышучы, үгезне кадап үтерүче кеше; 2. *перен. разг. шутл.* башлык, нинди дә булса эштә төп катнашучы).

**МАТЕМА'ТИК** *м.*— математик (1. математика белгече; 2. математика укытучысы; 3. математика факультеты студенты).

**МАТЕМА'ТИКА** *ж. мн.* нет — математика.

**МАТЕМАТИ'ЧЕСКИЙ** — математика...-ы; математик...; *математический анализ* — математик анализ. ◇ **Математический ум** — фикер йөртүе дөрес һәм анык булган кеше.

**МАТЕРЕ'ТЬ** *несов. простореч.*— олыгаю, зураю, күпне күрү, ныгу, чыныгу.

**МАТЕРИА'Л** *м.*— 1. материал (төрле әйберләрне хәзерләүгә китә торган чимал); *строительные материалы* — төзү материаллары; 2. *перен.* әсбап, материал; *учебные материалы* — уку-укыту әсбаплары; 3. тукыма, материя; *материал на пальто* — пальтолык материя; 4. *книж.* мәгълүмат, дәлил; *материалы для биографии Пушкина* — Пушкин биографиясе өчен мәгълүматлар.

**МАТЕРИАЛИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *филос.*— материализм (философиядә ике төп юнәлешнең берсе; идеализмга капма-каршы булган, материя дөньяның нигезен тәшкил итә һәм андагы күренешләрнең башлангычы булып тора, материя объектив яши һәм беренчел, ә аң аннан чыгарылма һәм икенчел, дөньяны һәм аның закончалыкларын танып белергә мөмкин дип өйрәтә торган бердәнбер фәнни юнәлеш).

**МАТЕРИАЛИ'СТ** I *м. филос.*— материалист (материализм тарафдары).

**МАТЕРИАЛИ'СТ** II *м. устар. неодобр.*— үз шәхси интересларын гына кайгыртучы, үз кесәсен генә кайгыртучы.

**МАТЕРИАЛИСТИ'ЧЕСКИЙ** *филос.*— материалистик; *материалистический подход к вопросу* — мәсьәләгә материалистик якын килү.

**МАТЕРИАЛИСТИ'ЧНЫЙ** *разг. устар. неодобр.*— комсыз, тик табыш турында гына уйлаучан; шәхси интересларга корылган.

**МАТЕРИАЛИ'СТСКИЙ** — материалистларча...; материалистларга хас; *материалистские взгляды* — материалистларга хас карашлар.

**МАТЕРИАЛОВЕ'Д** *м.* — материаловед (материаловедение белгече, галим).

**МАТЕРИАЛОВЕ'ДЕНИЕ** *ср. мн.* нет — материаловедение (төзү материаллары, чимал турындагы фән).

**МАТЕРИА'ЛЬНО** *нареч.* — материаль яктан, материаль як белән; *он в этом деле материально заинтересован* — аңа бу эш материаль яктан әһәмиятле; *материально он обеспечен* — ул материаль яктан тәэмин ителгән.

**МАТЕРИА'ЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет — материальлек, реальлек; *материальность мира* — дөньяның материальлеге (реальлеге).

**МАТЕРИА'ЛЬНЫЙ** — 1. материал...-ы; материаллар...-ы; *материальные склады* — материал складлары; *заведующий материальной частью* — материаллар бүлеге мөдире; 2. материаль; *материальное положение* — материаль хәл; *материальный мир* — материаль дөнья.

**МАТЕРИ'К** I *м. геогр.*— 1. материк, коры җир (җир шарының диңгезләр һәм океаннар белән әйләндереп алынган тоташ зур кисәге); 2. *спец.* туфрак асты (җирнең туфрак асты өлеше).

**МАТЕРИ'К** II *м. обл.*— карт җәнлек, күпне күргән җәнлек.

**МА'ТЕРИН** (а, о) *простореч.*— әнисенең ..-ы; *надела материно платье* — әнисенең күлмәген кигән.

**МАТЕРИ'НСКИЙ** — ана...-ы; аналарга хас; аналарча...; *материнская любовь* — ана мәхәббәте; *материнские заботы* — аналарча кайгырту.

**МАТЕРИ'НСТВО** *ср. мн.* нет, *книж.*— аналык, ана булу; *чувство материнства* — аналык хисе. ◇ **Охрана материнства и младенчества** — аналарны һәм балаларны саклау.

**МАТЕРИ'ТЬСЯ** *несов. вульг.*— сүгенү.

**МАТЕ'РИЯ** I *ж. мн.* нет — 1. *филос.* материя (кеше аңыннан бәйсез рәвештә яши һәм анда чагыла торган объектив реальлек); 2. *науч.* матдә; *строение материи* — матдәнең төзелеше; 3. *разг.* тема; *это — неинтересная материя* — бу кызыксыз тема.

**МАТЕ'РИЯ** II *ж.*— тукыма, материя; *шерстяная материя* — йон тукыма.

**МАТЕ'РИЯ** III *ж. мн.* нет, *мед.*— эрен, үлек; *из ушей течёт материя* — колаклардан эрен ага.

**МА'ТЕРНИЙ** *устар.* — к. материнский.

**МА'ТЕРНЫЙ** *вульг.*— начар, әшәке, сүгенү...-ы; *матерные слова* — сүгенү сүзләре.

**МАТЕРО'Й** *простореч.*— 1. көчле, олыгаеп җиткән, ныгып җиткән, чыныккан, карт, күпне күргән; *матерой волк* — олыгаеп җиткән, көчле, карт бүре; 2. *перен. неодобр.* чеп-чи, үтә, ата...; *матерой бюрократ* — чеп-чи бюрократ, үтә бюрократ, ата бюрократ.

**МАТЕ'РЧАТЫЙ** *разг.*— материядән эшләнгән, тукымадан эшләнгән; *книга в матерчатом переплёте* — материя белән тышланган китап.

**МАТЕРЩИ'НА** *ж. мн.* нет, *вульг.*— оятсыз сүгенү сүзләре, әшәке сүзләр.

**МАТЁРЫЙ** *обл.* — к. матерой.

**МА'ТЕРЬ** *ж. книж. торж. устар.* — ана.

**МАТИРОВА'ТЬ** *несов. спец.*— тоныкландыру, үтә күренмәс хәлгә китерү (мәсәлән, пыяланы).

**МА'ТИЦА** *ж. спец.*— матча.

**МА'ТКА** *ж.*— 1. *анат.* аналык; *болезни матки* — аналык авырулары; 2. *(самка)* ана хайван; 3. *(пчелиная матка)* ана корт, корт анасы; 4. *перен. спец.* калып; 5. *геол.* ана токым (эчендә руда яки кыйммәтле ташлар булган тау токымы); 6. *(главарь в играх) обл.* узаман, утаман; 7. *просторечь. обл.* әни, ана. ◇ **Правда-матка** *просторечь*—дөреслек, хакыйкать.

**МА'ТОВОСТЬ** *ж. мн.* нет — тоныклык, үтә күренмәү.

**МА'ТОВЫЙ** — 1. тонык, ялтыравыксыз; 2. үтә күренми торган.

**МА'ТОЧНИК** *м.*— 1. *спец.* ана корт күзәнәге; 2. *бот.* җимшән, җимешлек (үсемлекләрдә); 3. *с.-х.* ана терлекләрне караучы (терлекчелектә).

**МА'ТОЧНЫЙ** — 1. *мед. анат.* аналык...-ы; аналыктан...; *маточное кровотечение* — аналыктан кан китү; 2. колынлы бияләр...-ы; *маточный косяк* — колынлы бияләр өере. ◇ **Маточная порода** *геол.*— ана токым, нигез токым, төп токым (эчендә нинди дә булса башка бер кыйммәтле казылма ята торган тау токымы). **Маточный куст** — ботакларыннан үрчи торган куак (мәсәлән, кура җиләге).

**МАТРА'С, МАТРА'Ц** *м.*— матрас.

**МАТРА'СНИК, МАТРА'ЦНИК** *м. спец.*— матрас ясаучы (эшче).

**МАТРА'СНЫЙ, МАТРА'ЦНЫЙ** — матрас...-ы; *матрацная обивка* — матрас тышлыгы.

**МАТРИАРХА'ЛЬНЫЙ** *этнол.*— матриархат...-ы; матриархатка хас; матриархаль; матриархаттагыча; *матриархальное право* — матриархаль хокук; *матриархальные отношения* — матриархаль мөнәсәбәтләр.

**МАТРИАРХА'Т** *м. этнол.*— матриархат (борынгы ыруглык җәмгыятендә аналык стадиясе; җәмгыятьнең бу стадиясендә хуҗалык һәм җәмәгать тормышында җитәкчелек роле ана кулында булган).

**МАТРИМОНИА'ЛЬНЫЙ** *книж. устар. теперь шутл.*— өйләнешү...-ы; өйләнү...-ы; *матримониальные намерения* — өйләнү ниятләре.

**МА'ТРИЦА** *ж. тех.*— матрица, оя, калып (типографиядә, акча кою һәм штамплау эшендә кулланыла).

**МАТРИЦИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. тех. тип.*— матрицага салу, матрицалау, матрицасын алу.

**МАТРИЦИ'РОВАТЬСЯ** *несов. тех. тип.*— калыплану, матрицага салыну, матрицалану.

**МАТРИ'ЧНЫЙ** *тех. тип.*— матрица...-ы; *матричный картон* — матрица катыргысы.

**МАТРО'С** *м.*— матрос.

**МАТРО'СКА** *ж.*— 1. *просторечь.* матрос хатыны; 2. матроска (матрослар кия торган зур кайтарма якалы блуза).

**МАТРО'ССКИЙ** — матрос...-ы; матрослар...-ы; *матросская песня* — матрослар җыры.

**МА'ТУШКА** *ж.*— 1. *устар.* әни, әнкәем; 2. *разг. устар.* поп хатыны; 3. *просторечь. (в обращении к пожилой женщине)* ана-кай, апа.

**МАТЧ** *м. спорт.*— матч, ярыш; *шахматный матч* — шахмат ярышы.

**МАТЬ** *ж.*— әни, ана.

**МАТЬ-И-МА'ЧЕХА** и **МАТЬ-МА'ЧЕХА** *ж. мн.* нет, *бот.* — үги ана яфрагы (үлән).

**МА'УЗЕР** *м.*— маузер (автоматик пистолет яисә винтовканың бер төре).

**МАХ** *м. мн.* нет, *разг.*— бер әйләнеш (тәгәрмәчнең һ. б.); бер колач, бер кизәнеш. ◇ **Дать маху** *разг.*— ялгышу, хата ясау. **Одним (или единым) махом** или **с одного маху** *просторечь.*— бер кизәнү белән, бер кизәнүдә, бер селтәүдән, бер селтәү белән. **С маху** *разг.*— кинәт, саксыз.

**МАХА'ЛЬНЫЙ** *м. спец.*— селтәп сигнал бирүче.

**МАХА'ЛЬЩИК** *м. спец.*— к. махальный.

**МАХА'ТЬ** *несов. разг.*— 1. болгау, селкү, изәү; кагу; *махать рукой* — кул болгау; кул селкү, кул изәү; *машет крыльями* — канатларын кага; 2. *разг.* ишарәләү, ишарә белән чакыру, сигнал бирү.

**МАХА'ТЬСЯ** *несов. просторечь.*— җилпенү; *махаться платком* — яулык белән җилпенү.

**МАХИ'ЗМ** *м. филос.*— махизм (философиядә һәм теоретик физикада реакцион идеалистик агым, эмпириокритицизм).

**МАХИ'НА** *ж. разг.*— гаять зур әйбер, зур күләмле авыр әйбер.

**МАХИНА'ЦИЯ** *ж.*— махинация, интрига, астыртын хәйлә.

**МАХНО'ВЕЦ** *м. истор.* — махночы (Украинада гражданнар сугышы чорында Махно шайкасыннан булган бандит).

**МАХНО'ВЩИНА** *ж. мн.* нет — махночылар хәрәкәте (гражданнар сугышы чорында Украинада Махно җитәкчелегендә күтәрелгән кулаклар-бандитлар хәрәкәте).

**МАХНУ'ТЬ** *сов.*— 1. болгап кую, селкеп кую, кагып кую; 2. *просторечь.* ташлану, ыргытылу; 3. *разг.* сикерү; *махнуть с берега в воду* — ярдан суга сикерү; 4. *разг. фам.* китү, көтмәгәндә китеп бару, ычкыну; *я прежде всего поехал бы в Москву, потом махнул бы в Париж* (Чехов) — мин иң элек Москвага барыр идем, ә аннан соң Парижга ычкыныр идем. ◇ **Махнуть рукой** *разг.* кул селтәү (әһәмиятсез калдыру, ваз кичү мәгънәсендә).

**МАХОВИ'К** *м. тех.*— маховик (механизмның тигез ритм белән эшләп торуын тәэмин итүче тәгәрмәч).

**МАХОВО'Й:** 1. **маховое колесо** *тех.*— к. маховик; 2. **маховые перья** *зоол.*— чалгый каурыйлар (кошларда); 3. **маховая сажень** *обл.*— колач.

**МА'ХОМ** *нареч. простореч.*— бик тиз, күз ачып йомганчы, керфек какканчы.

**МА'ХОНЬКИЙ** *простореч.*— кечкенә генә, кеп-кечкенә, бәләкәй генә, нәни генә.

**МАХО'РКА** *ж. мн.* нет — махорка, тәмәке.

**МАХО'РОЧНЫЙ** — махорка...-ы; тәмәке ...-ы; *махорочная бумага* — тәмәке кәгазе.

**МАХО'ТКА** *ж. обл.*— кечкенә чүлмәк, тар муенлы чүлмәк.

**МАХРА'** I *ж. мн.* нет, *собир. обл.*— к. махры.

**МАХРА'** II *ж. мн.* нет, *простореч. фам.*— махра, тәмәке.

**МАХРО'ВЫЙ** — 1. *(о цветке)* катмарлы, чачаклы; *махровый мак* — катмарлы мәк; 2. *перен. разг. ирон.* ашып узган, чыкылдаган, чыкылдап торган, чеп-чи, мүкләнеп беткән; *махровый оппортунист* — чыкылдаган оппортунист.

**МАХРЫ'** *ед.* нет, *разг.*— чук, сәләмәләр (иске кием итәгендә асылынган сәләмә).

**МАЦО'НИ** *ж. нескл.*— әчегән сөт, катык (Кавказда).

**МА'ЧЕХА** *ж.*— үги ана.

**МА'ЧТА** *ж.*— мачта (суднода җилкән беркетү өчен утыртылган озын колга; электр чыбыгын элү өчен яки башка максат белән утыртылган багана).

**МАЧТОВО'Й** *м. мор.*— мачтовой (мачтада хезмәт итүче матрос).

**МА'ЧТОВЫЙ** — мачталык...; мачтага ярарлык; *мачтовый лес* — мачтага ярарлык агач материалы.

**МАШИ'НА** *ж.*— 1. машина; *вязальная машина* — бәйләү машинасы; 2. *простореч. устар.* поезд; 3. *разг.* автомобиль; *учрежденческая машина* — учреждение автомобиле; 4. *спорт.* велосипед, мотоцикл.

**МАШИНА'ЛЬНО** *нареч.*— аңсыз рәвештә, искәрмәстән, уйламыйча.

**МАШИНА'ЛЬНЫЙ** — уйламыйча...-ган, искәрмәстән...-ган, аңсыздан...-ган, ихтыярсыз...-ган; *машинальный ответ* — уйламыйча бирелгән җавап.

**МАШИНИЗА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет — к. машинизировать.

**МАШИНИЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.*— машиналаштыру, машиналар белән тәэмин итү; *машинизировать сельское хозяйство* — авыл хуҗалыгын машиналар белән тәэмин итү.

**МАШИНИ'СТ** *м.*— машинист, машина йөртүче.

**МАШИНИ'СТКА** *ж.*— машинистка (язу машинкасында эшләүче хатын-кыз).

**МАШИ'НКА** *ж.*— машинка; *пишущая машинка* — язу машинкасы; *машинка для стрижки* — чәч алу машинкасы.

**МАШИ'ННО-ТРА'КТОРНЫЙ** — машина-трактор...-ы; *машинно-тракторная станция* — машина-трактор станциясе.

**МАШИ'ННЫЙ** — 1. машина...-ы; *машинное масло* — машина мае; 2. машина белән..., машина ярдәмендә...; *машинное производство обуви* — аяк киемнәрен машина белән эшләп чыгару.

**МАШИНОВЕ'ДЕНИЕ** *ср. мн.* нет — машиноведение, машиналар турындагы фән.

**МАШИНОПИ'СНЫЙ** *спец.*— машинкада басылган; *машинописный текст* — машинкада басылган текст.

**МАШ'ИНОПИСЬ** *ж. мн.* нет, *спец.*— машинкада басу, язу машинкасында басу; *курсы машинописи* — машинкада басу курслары.

**МАШИНОСТРОЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *тех.*— машиналар төзү, машиналар эшләп чыгару.

**МАШИНОСТРОИ'ТЕЛЬНЫЙ** *тех.*— машиналар төзү...-ы; *машиностроительный завод* — машиналар төзү заводы.

**МАЭ'СТРО** *м. нескл.*— маэстро (1. *книж. устар.* атаклы музыкантларга бирелә торган хөрмәтле исем; 2. *шахм.* шахмат мастеры).

**МАЯ'К** *м.*— маяк (1. корабльләргә юл күрсәтү өчен сигнал уты булган, диңгез ярларына, утрауларга утыртылган биек башня; 2. *книж. ритор.* өмет символы, өмет эмблемасы; *Советский Союз — путеводный маяк для передового человечества* — Советлар Союзы — алдынгы кешелек дөньясы өчен юл күрсәтүче маяк).

**МА'ЯТНИК** *м.*— 1. *физ.* маятник; *маятник Фуко* — Фуко маятнигы; 2. тел; *часы с маятником* — телле сәгать; 3. *перен. пренебр.* һәрвакыт икеләнүчән кеше.

**МА'ЯТЬ** *несов. простореч.*— алҗыту, йөдәтү, борчу, арыту, газаплау.

**МА'ЯТЬСЯ** *несов. разг. фам.*— газаплану, җәфа чигү, газап чигү, борчылу; *весь день маялся перевозкой мебели* — көн буе мебель күчереп җәфа чиктем; *больной маялся всю ночь* — авыру төн буе газапланды.

**МАЯ'ЧИТЬ** *несов.* — ерактан күренү, ерактан күренеп тору, карачкылланып күренү.

**МАЯ'ЧНЫЙ** — маяк...-ы; *маячный огонёк* — маяк уты.

**МГА** *ж. мн.* нет — коры томан, рәшә.

**МГЛА** *ж. мн.* нет — 1. томанлы, тузанлы һава, караңгылык; 2. *поэт.* караңгылык; *ночная мгла* — төнге караңгылык.

**МГЛИ'СТЫЙ** — томанлы; *мглистый воздух* — томанлы һава

**МГНОВЕ'НИЕ** *книж.*— бик кыска вакыт, аз вакыт, күз ачып йомган ара. ◇ **В мгновение ока** *книж.*— бик тиз, күз ачып йомганчы, керфек какканчы.

**МГНОВЕ'ННО** — бик тиз, күз ачып йомганчы, керфек какканчы.

**МГНОВЕ'ННЫЙ** — 1. бик тиз ...-ган, кинәт була торган; *мгновенное решение* — бик тиз кабул ителгән карар; 2. *лингв.* к. взрывной II.

**МЕА'НДР** *м.*— 1. *геол.* борылма, борма (елгада); 2. *искус.* бормалы бизәк.

**МЕ'БЕЛЬ** *ж. мн.* нет — мебель, җиһаз, өй җиһазы (өстәл, урындыклар, диван, шкаф һ. б.).

**МЕ'БЕЛЬНЫЙ** — 1. мебель...-ы; *мебельный магазин* — мебель магазины; 2. мебельлек...; *мебельная материя* — мебельлек

материя (мебель тышлау өчен кулланыла торган материя).

**МЕ'БЕЛЬЩИК** *м. спец.*— мебель ясаучы, мебель остасы.

**МЕБЛИРО'ВАННЫЙ** — җиһазландырылган, мебель белән тәэмин ителгән.

**МЕБЛИРОВА'ТЬ** *сов.* и *несов.*— мебель урнаштыру, җиһазландыру, мебель белән тәэмин итү.

**МЕБЛИРОВА'ТЬСЯ** *несов.* — мебель урнаштырылу, җиһазландырылу, мебель белән тәэмин ителү.

**МЕБЛИРО'ВКА** *ж. мн.* нет — 1. к. меблировать; 2. мебель, җиһаз, йорт җиһазы.

**МЕБЛИРО'ВЩИК** *м. спец.* — мебель урнаштыручы, мебель куючы, җиһазлаучы, мебель белән тәэмин итүче.

**МЕГЕ'РА** *ж.*— усал хатын, үз сүзле хатын, килешмәүчән хатын.

**МЕГРЕ'ЛЫ** *мн.*— мегреллар (грузиннарның электә аерым бер этнографик группасы).

**МЁД** *м.*— 1. бал; 2. ачы бал (балны ачытып хәзерләнгән эчемлек). ◇ **Твоими устами да мёд бы пить** — авызыңа бал да май.

**МЕДАЛИ'СТ** *м.*, **МЕДАЛИ'СТКА** *ж.*— 1. медаль алган кеше; медальле кеше; 2. *спец.* күргәзмәдә медаль белән бүләкләнгән хайван (эт, ат һ. б.).

**МЕДА'ЛЬ** *ж.*— медаль. ◇ **Оборотная сторона медали** *перен.* — эшнең начар ягы.

**МЕДАЛЬЕ'Р** *м. спец.*— медальер (1. медаль кисүче художник; 2. к. медалист 2).

**МЕДАЛЬЕ'РКА** *ж.*— к. медальер.

**МЕДА'ЛЬНЫЙ** — 1. медаль...-ы; *медальный мастер* — медаль мастеры, медаль остасы; 2. медаль белән бүләкләү ...-ы; *медальная комиссия* — медаль белән бүләкләү комиссиясе.

**МЕДАЛЬО'Н** *м.*— медальон (зиннәт яки истәлек өчен эченә рәсем куеп муенга тагып йөртелә торган кечкенә юка коробка).

**МЕДВЕ'ДИНА** *ж. обл.*— 1. *только ед.* аю ите; 2. аю тиресе.

**МЕДВЕ'ДИХА** *ж. обл.*— к. медведица.

**МЕДВЕ'ДИЦА** *ж.*— ана аю.

**МЕДВЕ'ДКА** *ж.*— 1. *зоол.* аю чикерткә, бозаубаш (бөҗәк); 2. *обл.* тәбәнәк арба, кул арбасы; 3. *тех.* медведка (тешле тәгәрмәчләрдән торган һәм авыр әйберләр күтәрү өчен кулланыла торган җайланма); 4. *плот.* струг (ике кул белән тотып ышкылый торган ышкы).

**МЕДВЕ'ДЬ** *м.*— 1. *зоол.* аю; 2. *перен. разг. шутл.* авыр гәүдәле кеше, авыр кыймылдаучан кеше; әкрен кыймылдаучан кеше; 3. *разг. устар.* аю мехы; аю мехыннан тегелгән кием.

**МЕДВЕЖА'ТИНА** *ж. мн.* нет, *обл.*— к. медвежина.

**МЕДВЕЖА'ТНИК** *м. спец.*— 1. аю аулаучы; 2. аю йөртүче, аю биетүче; 3. аю эте; 4. аю читлеге.

**МЕДВЕЖА'ЧИЙ** — аю баласы...-ы; *медвежачья шкура* — аю баласы тиресе.

**МЕДВЕ'ЖИЙ** — 1. аю...-ы; *медвежья лапа* — аю табаны; 2. аю тиресеннән тегелгән; *медвежья шуба* — аю тиресеннән тегелгән тун. ◇ **Медвежий угол** *разг.* — аулак почмак, тын почмак. **Медвежья услуга** — каш ясыйм дип, күз чыгару. **Медвежья болезнь** *разг. шутл. эвф.*— куркудан эч китү. **Медвежье ухо** *бот.*— аю колак (үс.).

**МЕДВЕ'ЖИНА** *ж. мн.* нет — аю ите.

**МЕДВЕЖО'НОК** *м.* (*мн.* медвежата) — аю баласы.

**МЕДВЯ'НЫЙ** *поэт.*— баллы, хуш исле. ◇ **Медвяная роса** *бот.*— баллы чык.

**МЕДЕПЛАВИ'ЛЬНЫЙ** *тех.* — к. медноплавильный.

**МЕДЖИЛИ'С, МЕДЖЛИ'С** *м.*— мәҗлес (Иранда һәм Төркиядә закон чыгару палатасы, парламент).

**МЕДИА'НА** *ж.*— медиана (1. *мат.* өчпочмакның бер түбәсеннән аңа каршы яткан кырының уртасына төшерелгән туры сызык; 2. статистикада — урта зурлык).

**МЕДИА'ТОР** *м.*— медиатор (кыллы музыка коралларында уйнаганда кылларны чиртү өчен кулланыла торган махсус пластинка кисәге).

**МЕДИА'ЦИЯ** *ж. право* — медиация, арадашлык итү.

**МЕ'ДИК** *м.*— медик (1. *устар.* врач; 2. *разг.* медицина институты студенты).

**МЕДИКАМЕ'НТ** *м. книж.*— медикамент, дару.

**МЕДИЦИ'НА** *ж. мн.* нет — медицина (кеше организмындагы авыруларны дәвалау һәм авырулардан саклану юллары турындагы фән).

**МЕДИЦИ'НСКИЙ** — медицина...-ы; *медицинская помощь* — медицина ярдәме.

**МЕДИ'ЧКА** *ж.*— медичка (медицина институты студенткасы).

**МЕ'ДЛЕННО** *нареч.*— акрын, ашыкмыйча, озаклап.

**МЕ'ДЛЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет — акрынлык, озакка сузылу, акрын бару; *медленность работы* — эшнең акрынлыгы (озакка сузылуы).

**МЕ'ДЛЕННЫЙ** — озак, акрын, озакка сузылган.

**МЕДЛИ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— акрынлык, салмаклык, сүлпәнлек.

**МЕДЛИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.*— акрын, акрын хәрәкәт итә торган, салмак эшләнә торган, акрын үтәлә торган; *медлительные движения* — акрын хәрәкәтләр (салмак хәрәкәтләр).

**МЕ'ДЛИТЬ** *несов. книж.*— озаклау, озаклату, ашыкмау, озакка сузу, эшне озаклап эшләү, озак кыймылдау.

**МЕДЛЯ'К СТЕПНО'Й** *м. бот.*— дала кымырдавыгы (корткыч коңгыз).

**МЕ'ДНИК** *м.*— бакырчы (бакыр әйберләр ясаучы, төзәтүче).

**МЕДНОКРА'СНЫЙ** — җирән кызыл.

**МЕДНОЛИТЕ'ЙНЫЙ** *тех.*— бакыр кою ...-ы; *меднолитейный завод* — бакыр кою заводы.

**МЕДНОЛИТЕ'ЙЩИК** *м. спец.*— бакыр коючы (бакыр кою заводында эшләүче).

**МЕДНОЛО'БЫЙ** *разг. презрит.*— аңгыра, миңгерәү (кибәк баш).

**МЕДНОПЛАВИ'ЛЬНЫЙ** *тех.* — бакыр эретү...-ы; бакыр эретә торган; *медноплавильная печь* — бакыр эретү миче.

**МЕДНОПРОКА'ТНЫЙ** *тех.*— бакыр прокатлау...-ы; бакыр прокатлый торган; *меднопрокатный завод* — бакыр прокатлау заводы.

**МЕ'ДНЫЙ** — 1. бакыр...; *медная монета* — бакыр акча; 2. бакыр...-ы; *медная руда* — бакыр рудасы; 3. *простореч.* бакыр эшкәртү...-ы; *медный завод* — бакыр эшкәртү заводы. ◇ **Медный лоб** *разг. бран.*— кибәк баш (аңгыра, миңгерәү кеше турында). **Учился на медные гроши или на медные деньги** *разг. устар.*— ярлылык сәбәпле житәрлек белем ала алмадым.

**МЕДОВА'Р** *м. спец.*— бал кайнатучы, бал ачытучы, әче бал хәзерләүче.

**МЕДОВА'РЕННЫЙ** *спец.*— бал ачыту...-ы, бал хәзерләү...-ы; *медоваренное дело* — бал ачыту эше.

**МЕДОВА'РКА** *ж. спец. простореч.*— к. медоварня.

**МЕДО'ВЫЙ** — 1. бал...-ы; *медовый вкус* — бал тәме; 2. баллы; *медовые пряники* — баллы прянниклар. ◇ **Медовый месяц** *шутл.*— ширбәтле ай (өйләнешкәннән соң беренче ай). **Медовые речи** *устар.*— (бик күпне вәгъдә иткән) төче сүзләр. **Медовая роса** — баллы чык (температура үзгәрүдән агач яфракларында була торган татлы чык).

**МЕДОГО'НКА** *ж.*— бал суыргыч, бал кугыч, бал аерткыч.

**МЕДОНО'СНЫЙ** *книж. спец.*— 1. баллы; *медоносные цветы* — баллы чәчәкләр; 2. бал ташучы; *медоносные пчёлы* — бал ташучы кортлар (эшче кортлар).

**МЕДОСБО'Р** *м. с.-х.*— бал җыю.

**МЕДОТОЧИ'ВЫЙ** *книж. устар.*— төче телле, татлы телле, тасма телле.

**МЕДУ'ЗА** *ж. зоол.*— медуза (койкасыман тәнле диңгез хайваны).

**МЕДУНИ'ЦА** *ж.*— 1. *бот.* күкебаш; 2. *обл.* эшче корт.

**МЕДЬ** *ж. мн.* нет — 1. бакыр; 2. *разг.* бакыр акча.

**МЕДЯ'К** *м. простореч.*— бакыр акча.

**МЕДЯНИ'СТЫЙ** — бакырсыман, бакыр төсле.

**МЕДЯНИ'ЦА** *ж. зоол.*— аяксыз кәлтә, орчыкча. ◇ **Медяница грушевая** — груша борчасы (корткыч бөҗәк). **Медяница яблоневая** — алмагач борчасы.

**МЕДЯ'НКА** *ж.*— 1. *зоол.* бакыр елан, җиз елан; 2. *обл.* кара елан; 3. *обл.* аяксыз кәлтә елан; 4. *обл.* бакыр коңгыз; 5. *только ед. хим.* серкәле-бакырлы агулы тоз; 6. *спец.* шуннан хәзерләнгән яшел буяу.

**МЕДЯНО'Й, МЕДЯ'НЫЙ** *книж. устар.*— к. медный.

**МЕЖ** *предл. устар. книж.*— к. между.

**МЕЖА'** *ж.*— межа, ызан, чик.

**МЕЖБРО'ВЬЕ** *ср. книж.*— ике каш арасы.

**МЕЖВИДОВО'Й** *биол.*— төрле төр үсемлекләр арасындагы; төрле токым хайваннар арасындагы; *межвидовое скрещивание* — төрле төр үсемлекләр арасындагы серкәләнү.

**МЕЖДОМЕ'ТИЕ** *ср. грам.*— ымлык.

**МЕЖДОУ'ЗЛИЕ** *ср. бот.*— буын арасы (үсемлекләрдә).

**МЕЖДОУСО'БИЕ** *ср. книж. устар.*— үзара тынычсызлык, низаг, эчке буталыш, үзара тартыш, кычкырыш, сугыш, эчке чуалыш (мәсәлән, дәүләттәге төрле иҗтимагый группалар арасындагы тартыш).

**МЕЖДОУСО'БИЦА** *ж.*— к. междоусобие.

**МЕЖДОУСО'БНЫЙ** *книж. устар.*: **междоусобные войны** — үзара сугышлар.

**МЕ'ЖДУ** *предл. с твор. п.*— арасында, арасыннан; *дорога проходит между склоном горы и озером* — юл тау итәге белән күл арасыннан үтә; *между 1905-м и 1917-м годом (или годами)* — 1905 нче һәм 1917 нче еллар арасында. ◇ **Между делом** — эш арасында, бушаган арада. **Между нами говоря** *разг.*— үзара гына әйткәндә. **Пусть это останется между нами** — моны бездән башка беркем дә белергә тиеш түгел. **Между прочим** *разг.*— 1) *нареч.* болай гына; 2) *ввод. сл.* сүз уңаенда, сүз арасында, сүз җае килгәндә. **Между тем** *книж.*— 1) *нареч.* шул чакта, шул вакытта, шул арада; *между тем чай был выпит* — шул арада чәй эчелеп беткән иде; 2) *в знач. союза* чынында, асылда исә, хәлбуки, ләкин; *он кажется здоровым, между тем неизлечимо болен* — ул сәламәт күренә, ә асылда исә төзәлмәслек авыру.

**МЕЖДУВЕ'ДОМСТВЕННЫЙ** *офиц.*— ведомстволар арасындагы; *междуведомственная переписка* — ведомстволар арасындагы язышу.

**МЕЖДУГОРО'ДНИЙ** *устар.*, **МЕЖДУГОРО'ДНЫЙ** — шәһәрара; *междугородные телефоны* — шәһәрара телефоннар.

**МЕЖДУНАРО'ДНЫЙ** — халыкара; *международная политика* — халыкара политика.

**МЕЖДУПУ'ТЬЕ** *ср. ж.-д.*— ике (тимер) юл арасындагы полоса.

**МЕЖДУРЁБЕРНЫЙ** *анат.*— к. межрёберный.

**МЕЖДУРЕ'ЧЬЕ** *ср. книж.*— ике елга арасы.

**МЕЖДУГРЯ'ДНЫЙ** — түтәлләр арасындагы; *междугрядное пространство* — түтәлләр арасындагы бушлык.

**МЕЖДУРЯ'ДЬЕ** *ср. с.-х.*— түтәлләр арасы, рәтләр арасы.

**МЕЖДУСЕЛЕ'ННЫЙ** *спец.* — авыллар арасындагы; *междуселенная полоса* — авыллар арасындагы полоса.

**МЕЖДУСОЮ'ЗНИЧЕСКИЙ** *полит.* — союзниклар арасындагы; *междусоюзнические разногласия* — союзниклар арасындагы каршылыклар.

**МЕЖЕВА'ЛЬНЫЙ** *спец.*— межа ыручы, межа салучы, буразна сызучы.

**МЕЖЕВА'ТЬ** *несов. спец.*— межалау, межа яру, межа сызу, буразна сызу.

**МЕЖЕВО'Й** — межа...-ы; *межевые столбы* — межа баганалары.
**МЕЖЕВЩИ'К** *м. спец.* — землемер, жир үлчәүче, жир бүлеп бирүче.
**МЕЖЕ'ННЫЙ** *спец.* — урта биеклектәге; *меженные воды* — урта биеклектәге сулар.
**МЕЖЕ'НЬ** *ж.* — 1. *спец.* уртача тирәнлек, уртача биеклек (елгалардагы һәм күлләрдәге суларның уртача тирәнлеге); 2. *обл.* жәй уртасы, чиллә вакыты; *маленькие речки в межень высыхают* — кечкенә елгалар жәй уртасында (чилләдә) кибәләр.
**МЕЖЕУ'МОК** *м.* — 1. *обл.* урта зурлыктагы; *налим-межеумок* — урта зурлыктагы шамбы; 2. урта сортлы жеп; 3. *простореч. пренебр.* сантый, тинтәк кеше.
**МЕЖЕУ'МОЧНЫЙ** *обл.* и *простореч. пренебр.* — анык булмаган, ачык булмаган, томанлы, ярым-йорты; *межеумочное решение* — томанлы, анык булмаган карар.
**МЕЖЕУ'МЬЕ** *ср. мн.* нет, *простореч.* — тинтәклек, сантыйлык.
**МЕЖЗАВО'ДСКИЙ, МЕЖЗАВОДСКО'Й** — заводара...; *межзаводское совещание* — заводара киңәшмә.
**МЕЖЗУ'БНЫЙ** *лингв.* — теш арасы...ы; *межзубный звук* — теш арасы авазы (тел өске һәм аскы тешләр арасына куелган хәлдә әйтелә торган аваз).
**МЕЖКЛЕ'ТНЫЙ, МЕЖКЛЕ'ТОЧНЫЙ** *биол.* — күзәнәкләр арасындагы.
**МЕЖКОЛХО'ЗНЫЙ** — колхозара...; *межколхозная гидроэлектростанция* — колхозара гидроэлектростанция.
**МЕЖКО'СТНЫЙ** *анат. мед.* — сөякләр арасындагы.
**МЕЖНАЦИОНА'ЛЬНЫЙ** — милләтара...; милләтләр арасындагы; *межнациональный мир* — милләтләр арасындагы тынычлык, милләтара тынычлык.
**МЕЖНИ'К** *м. обл.* — 1. к. межполосье; 2. межага утыртылган агач.
**МЕЖПЛАНЕ'ТНЫЙ** *книжн.* — планетаара..., планеталар арасындагы; *межпланетное пространство* — планеталар арасындагы бушлык.
**МЕЖПОЛО'СЬЕ** *ср. с.-х.* — киң межа, киң ызан (серелгән кырлар арасында).
**МЕЖРАЙО'ННЫЙ** — районара...; *межрайонное соревнование* — районара ярыш.
**МЕЖРЁБЕРНЫЙ** *анат.* — кабыргалар арасындагы; *межрёберные мышцы* — кабыргалар арасындагы мускуллар.
**МЕЖЦЕХОВО'Й** *спец.* — цехара..., цехлар арасындагы; *межцеховое соревнование* — цехара ярыш, цехлар арасындагы ярыш.
**МЕЗАЛЬЯ'НС** *м. разг. устар.* — мезальянс (буржуаз-дворян җәмгыятьтә түбән катлау кешесе белән югары катлау кешесе арасында булган никах).
**МЕЗГА'** *ж. мн.* нет, *обл.* — 1. сыгынты, түп; *виноградная мезга* — виноград сыгынтысы; 2. *бот.* төслегән (яшь агач кайрысының эчке йомшак катлавы).
**МЕЗДРА'** *ж. мн.* нет, *спец.* — мездра (тиренең эчке ягындагы йомшак ярысы).
**МЕЗДРИ'ННЫЙ, МЕЗДРЯНО'Й** *спец.* — мездрадан хәзерләнгән; *мездринный клей* — мездрадан хәзерләнгән җилем.
**МЕЗДРИ'ТЬ** *несов. спец.* — мездрадан чистарту, мездрасын кыру (тиренең).
**МЕЗОЗО'Й, МЕЗОЗО'ЙСКАЯ ЭРА** *геол.* — мезозой эрасы (Җирнең геологик тарихында дүртенче эра).
**МЕЗОНИ'Н** *м.* — мезонин (чардак өй, өй өстенә ясалган кечкенә өскормa, тулы булмаган өске этаж).
**МЕ'КАТЬ** *несов. простореч.* — мәэлдәү (сарык); кычкыру (бозау), мөгрәү (сыер).
**МЕКСИКА'НЕЦ** *м.* — мексикалы, Мексика кешесе.
**МЕЛ** *м. мн.* нет — акбур, бур.
**МЕЛАНХО'ЛИК** *м.*, **МЕЛАНХОЛИ'ЧКА** *ж. книж.* — меланхолик (1. *мед.* меланхолия белән авыручы; 2. меланхолик темпераментлы кеше, күңелсезлеккә, төшенкелеккә бирелүчән кеше).
**МЕЛАНХОЛИ'ЧЕСКИЙ** *книж.* — 1. меланхолик; *меланхолический характер* — меланхолик характер; 2. күңелсез, эч пошыргыч; кайгылы; *меланхолическая песня* — күңелсез җыр.
**МЕЛАНХОЛИ'ЧНЫЙ** — төшенкелеккә бирелүчән; *меланхоличный характер* — төшенкелеккә бирелүчән характер.
**МЕЛАНХО'ЛИЯ** *ж. мн.* нет, *книж.* — меланхолия (1. *мед.* күңел төшенкелегенә бирелү авыруы; 2. күңел төшенкелеге, эч пошу, боеклык). ◇ **Чёрная меланхолия** *разг.* — боеклык, кәефсезлек, күңел төшенкелеге.
**МЕЛЕ'ТЬ** *несов.* — саегу; *река мелеет* — елга саега.
**МЕЛИЗНА'** *ж. мн.* нет, *разг.* — сайлык.
**МЕЛИНИ'Т** *м. мн.* нет, *хим.* — мелинит (шартлагыч матдә).
**МЕЛИНИ'ТОВЫЙ** *хим.* — мелинитлы; *мелинитовый снаряд* — милинитлы снаряд.
**МЕЛИОРАТИ'ВНЫЙ** *с.-х.* — 1. мелиорация...-ы; *мелиоративные работы* — мелиорация эшләре; 2. мелиорация өчен билгеләнгән; *мелиоративный кредит* — мелиорация өчен билгеләнгән кредит.
**МЕЛИОРА'ТОР** *м. с.-х.* — мелиоратор, мелиорация белгече.
**МЕЛИОРАЦИО'ННЫЙ** — к. мелиоративный.
**МЕЛИОРА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *с.-х.* — мелиорация (сазлыкларны киптерү, коры һәм эшкә яраксыз җирләрне сугару юллары белән аларны иген игү өчен яраклы хәлгә китерү һәм уңдырышлылыгын арттыру).
**МЕЛИ'ССА** *ж. бот.* — мелисса, лимон бөтнеге (үс.).
**МЕ'ЛИСТЫЙ** *спец.* — акбурсыман, акбурга охшаган, бурга охшаган.
**МЕЛИ'ТЬ** I *несов. простореч.* — ваклау.
**МЕЛИ'ТЬ** II *несов.* — акбур сөртү, акбур белән ышку, акбурлау (мәсәлән, бильярд киен).
**МЕ'ЛКИЙ** — 1. вак, кечкенә; *разорвала письмо на мелкие кусочки* — хатны вак кисәкләргә ерткалады; 2. сай; *мелкая та-*

*релка* — сай тәлинкә; *мелкая пахота* — сай сөрү; 3. *социол.* вак; *мелкое хозяйство* — вак хуҗалык; *мелкая буржуазия* — вак буржуазия. ◇ Мелкая душа *перен.* — вак кеше, түбән кеше. Мелкая сошка *разг. устар.* — әһәмиятсез кеше, авторитетсыз кеше. Мелким бесом (рассыпаться) — ялагайлану, тәлинкә тоту. Мелкие заботы — вак-төяк мәшәкатьләр.

**МЕ'ЛКО** *нареч.* — 1. вак итеп; *мелко наколоть сахар* — шикәрне вак итеп вату; 2. сай; *пахать мелко* — сай сөрү. ◇ Мелко плавать *разг.* — сайдан йөзү, сай йөзү (нинди дә булса эштә сәләтсез, белемсез, көчсез булу).

**МЕЛКОБО'РТНЫЙ** *мор.* и *спорт.* — тәбәнәк бортлы; тәбәнәк кырыйлы; *мелкобортные лодки* — тәбәнәк бортлы көймәләр.

**МЕЛКОБУРЖУА'ЗНЫЙ** — вак буржуазия...-ы; вак буржуаз...; *мелкобуржуазная теория* — вак буржуаз теория.

**МЕЛКОВО'ДНЫЙ** — сай; *мелководная река* — сай елга.

**МЕЛКОВО'ДЬЕ** *ср. мн.* нет — 1. сайлык (су азлык); 2. су саеккан вакыт.

**МЕЛКОДО'ННЫЙ** *спец.* — сай, сай төпле; *мелкодонная лодка* — сай (төпле) көймә.

**МЕЛКОЗЕРНИ'СТЫЙ** *спец.* — вак бөртекле; *мелкозернистая рожь* — вак бөртекле арыш.

**МЕЛКОЗУ'БКА** *ж. спец.* — вак тешле пычкы.

**МЕЛКОЗУ'БЧА'ТЫЙ** *спец.* — вак тешле; *мелкозубчатое колесо* — вак тешле тәгәрмәч.

**МЕЛКОЗУ'БЫЙ** — кечкенә тешле, вак тешле; *мелкозубая рыба* — вак тешле балык.

**МЕЛКОКАЛИ'БЕРНЫЙ** — 1. *спец.* кечкенә калибрлы; *мелкокалиберная винтовка* — кечкенә калибрлы винтовка; 2. *перен. разг. устар.* тар карашлы; *мелкокалиберный человек* — тар карашлы кеше.

**МЕЛКОКРЕСТЬЯ'НСКИЙ** *социол.* — вак хуҗалыклы крестьян...-ы; *мелкокрестьянские деревни* — вак хуҗалыклы крестьян авыллары.

**МЕЛКОЛЕПЕ'СТНИК** *м. бот.* — вакбаш (чүп үлән).

**МЕЛКОЛЕ'СЬЕ** *ср. мн.* нет — куаклык, вак урманлык, вак агачлык.

**МЕЛКОПОМЕ'СТНЫЙ** *истор. социол.* — кечкенә поместьелы; *мелкопоместный дворянин* — кечкенә поместьелы дворян.

**МЕЛКОСО'БСТВЕННИЧЕСКИЙ** *социол.* — вак милекчелек...-ы; вак милекчеләрдән тора торган; *мелкособственническое крестьянское хозяйство* — вак милекчеләрдән тора торган крестьян хуҗалыгы; *мелкособственнические интересы* — вак милекчелек интереслары.

**МЕ'ЛКОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. ваклык; *мелкость рыбы* — балыкның ваклыгы; 2. сайлык; *мелкость пруда* — буаның сайлыгы. ◇ Мелкость души — түбәнлек, ваксыллык, ваклык.

**МЕЛКОТА'** *ж. мн.* нет. *простореч.* — 1. к. мелкость 1; 2. *собир. шутл. фам.* кечкенәләр, бала-чага; вак-төяк; *все взрослые на работе, дома осталась одна мелкота* — зурлар барысы да эштә, өйдә бары бала-чага гына калган.

**МЕЛКОТОВА'РНЫЙ** *экон.* — вак товар...-ы; *мелкотоварное хозяйство* — вак товар хуҗалыгы.

**МЕЛКОТРА'ВЧАТЫЙ** — 1. *устар.* үләнгә охшаган вак бизәкле; *мелкотравчатый атлас* — үләнгә охшаган вак бизәкле атлас; 2. *перен. шутл. простореч.* вак, түбән, әһәмиятсез; *мелкотравчатый человек* — вак кеше, түбән кеше, әһәмиятсез кеше.

**МЕЛКОШЁРСТНЫЙ, МЕЛКОШЁРСТЫЙ** *спец.* — кыска йонлы.

**МЕЛОВА'ТЫЙ** *спец.* — бераз акбурлы, составына бераз акбур кергән; *меловатая почва* — бераз акбурлы туфрак, составына бераз акбур кергән туфрак.

**МЕЛОВО'Й** — 1. акбур... ы; *меловые горы* — акбур таулары; 2. акбурлы; *меловая бумага* — акбурлы кәгазь.

**МЕЛОВЩИ'К** *м. устар.* — акбур сатучы.

**МЕЛОДЕКЛАМА'ТОР** *м. искус.* — мелодекламатор.

**МЕЛОДЕКЛАМА'ЦИЯ** *ж. искус.* — 1. к. мелодекламировать; 2. мелодекламация (музыкага няреп (кушылып) укыла торган декламация).

**МЕЛОДЕКЛАМИ'РОВАТЬ** *несов. искус.* — музыкага няреп (кушылып) декламация уку.

**МЕЛО'ДИКА** *ж. мн.* нет, *муз. лит.* — 1. мелодика (көйләр турындагы фән); 2. аһәнлелек; *мелодика стиха* — шигырьнең аһәнлелеге.

**МЕЛОДИ'ЧЕСКИЙ** *книж.* — 1. *муз.* мелодик, мелодика таләпләренә яраклы; *мелодическая фигура* — мелодик фигура; 2. к. мелодичный.

**МЕЛОДИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — аһәнлелек, моңлылык.

**МЕЛОДИ'ЧНЫЙ** — аһәнле, ягымлы, моңлы; *мелодичный напев* — моңлы көй; *мелодичный голос* — ягымлы тавыш.

**МЕЛО'ДИЯ** *ж. муз.* — көй, моң, мелодия.

**МЕЛОДРА'МА** *ж. книж.* — мелодрама (1. *устар.* музыкалы һәм җырлы драма; 2. *лит.* авыр кичерешле драма әсәре).

**МЕЛОДРАМАТИ'ЧЕСКИЙ** *книж.* — мелодрама...-ы; мелодрамага хас; *мелодраматический сюжет* — мелодрамага хас сюжет.

**МЕЛОДРАМАТИ'ЧНЫЙ** *книж.* — авыр һәм кызганыч; *мелодраматичная сцена* — авыр һәм кызганыч күренеш.

**МЕЛО'К** *м.* — акбур кисәге.

**МЕЛОМА'Н** *м.*, **МЕЛОМА'НКА** *ж. книж.* — җыр һәм музыка һәвәскәре, җыр һәм музыка яратучы.

**МЕЛОМА'НИЯ** *ж. книж.* — җырга һәм музыкага һәвәслек, җыр һәм музыка ярату.

**МЕЛОЧИ'ШКА** *ж. разг. пренебр.* — к. мелочь.

**МЕЛОЧНО'Й** I *устар.* — вак; *мелочной товар* — вак товар; *мелочная торговля* — вак сәүдә.

**МЕЛОЧНО'Й** II — к. мелочный.

**МЕ'ЛОЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — ваклык, әһәмиятсезлек; *мелочность наблюдений* — күзәтүләрнең әһәмиятсезлеге. ◇ **Мелочность души** — түбәнлек.

**МЕ'ЛОЧНЫЙ** *разг.* — 1. вакчыл, вак; *мелочный человек* — вакчыл кеше; 2. *перен.* әһәмиятсез, вак, түбән, вак-төяк; *мелочные интересы* — вак интереслар, түбән интереслар; *мелочный факт* — әһәмиятсез факт; *мелочные ссоры* — вак-төяк ызгышлар.

**МЕ'ЛОЧЬ** *ж.* — 1. *только ед. собир.* вак-төяк, вак; *крупные ягоды съел, осталась мелочь* — эре җиләкләрне ашап бетердем, вак-төягә генә калды; 2. *только ед. собир.* вак акча; *дать сдачи мелочью* — вак акча кайтарып бирү; 3. *перен. разг. фам.* вак-төяк, юк-бар нәрсә. ◇ **Размениваться на мелочи или по мелочам** — вак-төяк белән вакыт уздыру, юк-бар (нәрсә) белән шөгыльләнү.

**МЕЛЬ** *ж.* — сайлык, сай урын (күлдә, елгада, диңгездә). ◇ **Сидеть (как рак) на мели** *разг. перен.* — көймә комга утыру (бик уңайсыз хәлдә булу мәгънәсендә).

**МЕЛЬКА'ТЬ** *несов.* — 1. күренеп-күренеп китү, ялтырап-ялтырап китү, ялт-йолт итеп күренү, күзгә чагылу, күзгә чалыну; *вдали мелькала молния* — еракта яшен ялтырап-ялтырап китә иде; *за окном вагона изредка мелькали деревья* — вагон тәрәзәсеннән ара-тирә агачлар күзгә чалына иде; 2. җем-җем итү, җемелдәп күренү; *вдали мелькают огни* — еракта утлар җемелдәп күренә.

**МЕЛЬКНУ'ТЬ** *однокр.* — күренеп китү, җемелдәп китү, күзгә чалынып китү. ◇ **У меня в голове мелькнула мысль** — башыма бер уй килде, башымда бер фикер туды. **На лице её мелькнула усмешка** — аның йөзендә мәсхәрәле елмаю чагылып китте.

**МЕ'ЛЬКОМ** *нареч.* — 1. кыска вакытка гына; *мне не удалось даже мельком с ним повидаться* — миңа аның белән кыска вакытка гына булса да күрешергә туры килмәде; 2. читләтеп кенә, өстән-өстән генә; *я об этом слышал только мельком* — мин бу турыда читләтеп кенә ишетеп калдым.

**МЕ'ЛЬНИК** *м.* — тегермәнче, тегермән хуҗасы, тегермәндә эшләүче.

**МЕ'ЛЬНИЦА** *ж.* — тегермән; *водяная мельница* — су тегермәне; *кофейная мельница* — кофе тегермәне. ◇ **Лить воду на чью-н. мельницу** — кемнең дә булса тегермәненә су кою (берәр кешенең файдасына эш итү мәгънәсендә).

**МЕ'ЛЬНИЧАТЬ** *несов. обл.* — тегермәнче булып эшләү, тегермәнчелек итү

**МЕ'ЛЬНИЧИЙ** *обл.* — 1. тегермәнче...-ы; *мельничий фартук* — тегермәнче алъяпкычы; 2. *в знач. сказ.* тегермәнченеке; *этот фартук мельничий* — бу алъяпкыч тегермәнченеке

**МЕЛЬНИЧИ'ХА** *ж. разг.* — 1. тегермәнче (хатын-кыз); 2. тегермәнче хатыны.

**МЕ'ЛЬНИЧНЫЙ** — тегермән..-ы; *мельничные колёса* — тегермән чарыклары.

**МЕЛЬТЕШИ'ТЬ** *несов. обл.* — күз алдында буталу; *мельтешат перед глазами бесконечные цифры* — күз алдында очсыз-кырыйсыз цифрлар бутала.

**МЕЛЬХИО'Р** *м. мн.* нет — мельхиор (бакырның никель белән катнашмасы).

**МЕЛЬХИО'РОВЫЙ** — мельхиор...; мельхиордан ясалган; *мельхиоровые ложки* — мельхиор кашыклар.

**МЕЛЬЧА'ЙШИЙ** *книж.* — иң вак, иң кечкенә.

**МЕЛЬЧА'ТЬ** *несов.* — 1. ваклану, вагаю, кечерәю; *от плохого ухода скот мельчает* — начар тәрбияләү аркасында терлек вагая; 2. *перен.* түбәнлеккә төшү; *в мещанской среде люди мельчают* — мещаннар арасында кешеләр түбәнлеккә төшәләр.

**МЕ'ЛЬЧЕ** — ваграк; сайрак.

**МЕЛЬЧИ'ТЬ** *несов. разг.* — 1. (*крошить на мелкие кусочки*) ваклау, вак кисәкләргә бүлү, турау; 2. (*делать более мелким*) вагайту, кечерәйтү.

**МЕЛЮЗГА'** *ж. мн.* нет, *собир. разг. пренебр.* — 1. вак балыклар; вак хайваннар; 2. бала-чага, кечкенә балалар; 3. (*незначительные люди*) әһәмиятсез кешеләр.

**МЕМБРА'НА** *ж. физ. тех.* — мембрана (электр тирбәнешләрен һәм механик тирбәнешләрне аваз тирбәнешләренә һәм киресенчә әверелдерүдә кулланыла торган яры яки сыгылма материалдан эшләнгән юка пластинка).

**МЕМОРА'НДУМ** *м. офиц.* — меморандум (1. хөкүмәтнең карашларын чагылдырган дипломатик нота; 2. төрле учреждениеләрдә — аңлатма язуы; 3. *торг.* нәрсә турында булса да искәртү язуы).

**МЕМОРИА'Л** *м.* — мемориал (1. *устар.* көндәлек дәфтәр; 2. *спец. устар.* сәүдә эшендә көндәлек оборот язып барыла торган бухгалтерия кенәгәсе).

**МЕМОРИА'ЛЬНЫЙ** *спец. устар.* — мемориаль...; *мемориальная доска* — мемориаль такта (берәр данлыклы вакыйганың яки атаклы кешенең истәлеген мәңгеләштерү максаты белән язып куелган такта).

**МЕМО'РИЯ** *ж. канц. устар.* — мемория (нинди дә булса бер эшнең эчтәлеге турындагы кыскача язма).

**МЕМУАРИ'СТ** *м.*, **МЕМУАРИ'СТКА** *ж. книж. лит.* — мемуарист, мемуарлар язучы.

**МЕМУА'РНЫЙ** *лит.* — мемуар...; *мемуарная литература* — мемуар әдәбият.

**МЕМУА'РЫ** *м. ед.* нет — мемуарлар (1. *лит.* баштан үткән, күргән һәм ишеткән вакыйгалар турында әдәби әсәр; 2. *устар.* гыйльми учреждениеләр тарафыннан чыгарылган фәнни хезмәтләр).

**МЕ'НА** *ж.* — 1. алмашу, алмаштыру, алышу, алыштыру; 2. *право* алышу договоры.

**МЕНАЖЁР** *м. спорт.* — менажёр (спортсменның ярыш вакытында ярдәм итүчесе, сакчысы).

**МЕНАЖИ'РОВАТЬ** *несов. спорт.* — саклау, ярдәм итү (ярыш вакытында спортсменга).

**МЕ'НЕЕ** *книж. устар.* — азрак, кимрәк; *менее двух месяцев* — ике айдан кимрәк. ◇ **Тем не менее** *книж.* — аңа карамастан, шулай да, шулай булса да. **Более или менее; не более, не менее, как...** — к. более.

**МЕНЕСТРЕ'ЛЬ** *м. истор.* — сәяхәтче шагыйрь-музыкант, трубадур (урта йөзләрдә).

**МЕ'НЗУЛА** *ж. тех.* — мензула (җир өстенең планын һәм карталарын төшергәндә кулланыла торган инструмент).

**МЕ'НЗУЛЬНЫЙ** *тех.* — мензула...-ы; *мензульная ручка* — мензула тоткасы.

**МЕНЗУ'РКА** *ж. спец.* — мензурка (сыек әйберләрнең күләмен үлчәү өчен кулланыла торган пыяла савыт).

**МЕНЗУ'РОЧНЫЙ** *спец.* — мензурка...-ы; *мензурочное дно* — мензурка төбе.

**МЕ'НИВАТЬ** *разг. многокр.* — алмаштыргалау.

**МЕНИНГИ'Т** *м. мед.* — менингит (ми тышчасы ялкынсыну авыруы).

**МЕНОВО'Й** *экон. торг.* — алмашу...-ы; алыштыру...-ы; *меновая единица* — алмашу берәмлеге.

**МЕНОВЩИ'К** *м. торг. устар.* — алыштыручы (бер товарны икенче товарга алыштырып сәүдә итүче).

**МЕНСТРУА'ЛЬНЫЙ** *мед.* — менструация...-ы; күрем...-ы; айлыклар...-ы; *менструальный период* — күрем чоры, менструация чоры.

**МЕНСТРУА'ЦИЯ** *ж. мед.* — менструация, күрем, айлыклар.

**МЕНСТРУИ'РОВАТЬ** *несов. мед.* — күрем күрү, айлыклар килү.

**МЕ'НТОР** *м. книж. устар., теперь ирон.* — ментор, тәрбияче, өйрәтүче.

**МЕ'НТОРСКИЙ** *книж. устар., теперь ирон.* — ментор...-ы; менторларча...; тәрбияче...-ы; *менторский тон* — менторлар тоны, тәрбиячеләр тоны.

**МЕНУЭ'Т** *м.* — менуэт (1. борынгы француз биюе; 2. *муз.* шул бию ритмына салынган музыкаль әсәр).

**МЕ'НЬШЕ** — 1. кечкенәрәк, кечерәк; 2. азрак, кимрәк.

**МЕНЬШЕВИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *полит. истор.* — меньшевизм (рус социал-демократиясендә марксизмга дошман булган һәм социалистик революция җиңгәннән соң халык дошманнарының тереге булып әверелгән оппортунистик агым, эшчеләр хәрәкәтендә буржуазия агентурасы).

**МЕНЬШЕВИ'К** *м.*, **МЕНЬШЕВИ'ЧКА** *ж. полит.* — меньшевик, меньшевичка, меньшевизм тарафдары.

**МЕНЬШЕВИ'СТСКИЙ** *полит.* — меньшевистик; *меньшевистские лозунги* — меньшевистик лозунглар.

**МЕ'НЬШИЙ** — 1. кечерәк, кечкенәрәк; *он выбрал меньшую* — ул кечкенәрәген сайлады; 2. *книж.* иң кечкенә; 3. *разг.* к. младший. ◇ **По меньшей мере** — к. мера.

**Самое меньшее** — аз дигәндә, иң азында, иң азы, иң кимендә.

**МЕНЬШИНСТВО'** *ср. книж.* — азчылык; *меньшинство голосов* — азчылык тавыш.

**МЕНЬШО'Й** *простореч.* — к. младший.

**МЕНЮ'** *нескл. ср.* — меню (ашханәдәге ашамлыкларның исемлеге).

**МЕНЯ'ЛА** *м. разг. устар.* — акча ваклаучы (акча ваклау эшен кәсеп итеп алган кеше).

**МЕНЯ'ЛЬНЫЙ** *торг.* — акча ваклау...-ы; *меняльная контора* — акча ваклау конторасы.

**МЕНЯ'ЛЬЩИК** *м. простореч. спец.* — к. меновщик и меняла.

**МЕНЯ'ТЬ** *несов.* — 1. (*обменивать*) алышу, алмашу; 2. алыштыру, алмаштыру; *менять бельё* — бельёны алыштыру; 3. үзгәртү; *менять убеждения* — карашларны үзгәртү; 4. ваклау; *менять деньги* — акча ваклау. ◇ **Менять кукушку на ястреба** *поговорка* — сыер биреп энә алу, балта биреп шөшле алу (файдасыз алыш-биреш).

**МЕНЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. алышу; *меняться квартирами* — квартираларны алышу; 2. (*изменяться*) үзгәрү, алмашыну; 3. *страд.* алыштырылу, алмаштырылу. ◇ **Меняться в лице** — чырае үзгәрү.

**МЕ'РА** *ж.* — 1. үлчәү берәмлеге; *мера длины* — озынлык үлчәве берәмлеге; 2. чама; *знать меру* — чаманы белү; 3. чара; *решительные меры* — кискен чаралар; 4. *офиц.* дәрәҗә; *мера вины* — гаепнең дәрәҗәсе; 5. *устар. лит.* шигырь үлчәве. ◇ **Без меры** — чамасыз, чиктән тыш. **Сверх меры, чрез меру** — чиктән тыш, үтә, чамасыз, ифрат, үлчәүсез. **В меру** — кирәк кадәр, кирәгенчә, җитәрлек. **По мере сил** — хәлдән килгәнчә, кулдан килгәнчә, көч җиткәненчә. **По мере возможности** — мөмкин булганча, мөмкин булуга карап. **По мере надобности** — кирәк булган саен, кирәк булуына карап. **По меньшей мере** — иң кимендә, кимендә, аз дигәндә. **По крайней мере** — к. крайний. **В полной мере** — тулысынча, җитәрлек. **Ни в какой мере** — *канц.* — берничек тә.

**МЕ'РГЕЛЬ** *м. мн.* нет, *геол.* — мергель (кызыл балчыклы известьташ).

**МЕРЁЖА** *ж. обл. спец.* — балык (тоту) ятьмәсе.

**МЕРЁЖКА, МЕРЕ'ЖКА** *ж. спец.* — 1. мережка (аркау җепләрен суырып алып, материягә эшләнгән челтәр); 2. *обл.* кечкенә ятьмә.

**МЕРЕ'ТЬ** *несов. разг.* — 1. кырылу, күпләп үлү; *мрут как мухи* — чебен шикелле (чебендәй) кырылалар; 2. (*сжиматься, замирать*) кысылу, тараю, тукталып калу (йөрәк, тын алу турында).

**МЕРЕ'ЩИТЬСЯ** *несов.* — күзгә күренү, күренгән шикелле булу, күз алдына килү; юк әйбер бар булып күренү.

**МЕРЕЯ'** *ж. спец.* — күнгә төшерелгән бизәк.

**МЕРЗА'ВЕЦ** *м.*, **МЕРЗА'ВКА** *ж. разг. бран.* — әшәке, кабахәт, әхлаксыз, азгын (кеше).

**МЕРЗЕ'ТЬ** *несов. простореч. вульг.* — кабахәтләнү, әшәкеләнү, әхлаксызлану.

**МЕРЗИ'ТЬ** *несов. простореч.* — нәфрәт тудыру (үзенә карата, кемдә дә булса).

**МЕ'РЗКИЙ** — 1. жирәндергеч, чирканыч, нәфрәт уята торган, кабахәт; *мерзкие поступки*—жирәндергеч кыланышлар; 2. *разг. фам.* начар, күңелсез; *мерзкая погода* — начар (күңелсез) һава.

**МЁРЗЛОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — туңган булу, туңганлык; *мёрзлость почвы* — туфракның туңган булуы.

**МЕРЗЛОТА'** — туфракның туңган катлавы.

**МЁРЗЛЫЙ** — 1. туң, туңган, катккан; *мёрзлая земля* — туңган жир; 2. өшегән, өшеп бозылган; *мёрзлый картофель* — өшегән бәрәңге.

**МЕРЗЛЯ'К** *м. разг. фам.* — туңучан, өшүчән, салкыннан куркучан, күшегүчән, кышлыксыз (кеше).

**МЕРЗЛЯ'ТИНА** *ж. мн.* нет, *простореч. пренебр.* — 1. к. мерзляк; 2. өшегән азыклар, өшеп бозылган азыклар.

**МЁРЗНУТЬ** *несов.* — 1. бик нык туңу, өшү; *руки мёрзнут* — кулларым бик нык туңа; 2. *разг.* кату; *вода мёрзнет* — су ката.

**МЕРЗОПА'КОСТНЫЙ** *разг. фам.* — чиктән тыш начар, чиктән тыш кабахәт, чиктән тыш әшәке, бик жирәнгеч; *произошла мерзопакостная история* — бик жирәнгеч вакыйга булып үтте.

**МЕ'РЗОСТНЫЙ** *книж. устар.* — к. мерзопакостный.

**МЕ'РЗОСТЬ** *ж.* — 1. *только ед. книж. устар.* кабахәтлек, әшәкелек, жирәнгечлек; 2. *разг.* начар әйбер; начар мөгамәлә, начар эш. ◇ **Говорить мерзости** — әшәке сүзләр сөйләү.

**МЕРИДИА'Н** *м.* — меридиан (жир шарының полюслары аша үтә һәм экваторны туры почмак ясап кисә торган уйланма түгәрәк сызык).

**МЕРИДИОНА'ЛЬНЫЙ** *науч.* — меридиональ...; меридиан юнәлешендә...; *меридиональная линия* — меридиональ сызык; *мериодинальное направление цепи гор* — тауларның меридиан юнәлешендә тезелүләре.

**МЕРИ'ЛО** *ср. книж.* — 1. *устар.* к. мера 1; 2. критерий, үлчәү, чама, үлчәгеч, үлчәү үрнәге.

**МЕРИ'ЛЬНЫЙ** *тех.*— үлчәү...-ы; *мерильный инструмент* — үлчәү инструменты.

**МЕРИ'ЛЬЩИК** *м.*, **МЕРИ'ЛЬЩИЦА** *ж. тех.* — үлчәүче (эшче).

**МЕ'РИН** *м.* — 1. алаша (ат). ◇ **Как сивый мерин** *простореч. вульг.*: **врёт, как сивый мерин** — күзгә карап ялганлый, оятсыз рәвештә ялганлый; **глуп, ленив, как сивый мерин** — карт алаша кебек ялкау, аңгыра.

**МЕРИНО'С** *м.* — меринос (1. йомшак һәм нечкә йонлы сарык токымы; 2. *только ед.* шундый сарыкның йоны; 3. *только ед.* шул йоннан эшләнгән тукыма).

**МЕРИНО'СОВЫЙ** — 1. меринос...-ы; *мериносовая шерсть* — меринос йоны; 2. меринос йонынnan...-ган; *мериносовая шаль*— меринос йонынnan бәйләнгән шәл.

**МЕРИ'ТЕЛЬНЫЙ** *спец.* — к. измерительный.

**МЕ'РИТЬ** *несов. разг.*— 1. үлчәү; *мерить комнату* — бүлмәне үлчәү; 2. (*примерять*) киеп карау; *мерить костюм* — костюмны киеп карау. ◇ **Мерить на свой аршин** — үз аршынына үлчәү. **Мерить вёрсты** *шутл. простореч.* — чакрым баганаларын санау (ерак юл йөрү мәгънәсендә). **Мерить в ту же меру, тою же мерою** — ни бирсәң, шуны алырсың.

**МЕ'РИТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. *разг.* үлчәшү; сынашу; *мериться ростом* — буйларны үлчәшү; *мериться силами* — көчләрне сынашу; 2. *страд.* үлчәнү; *материя мерится метром* — материя метр белән үлчәнә.

**МЕ'РКА** *ж.* — 1. *разг.* үлчәү; *портной сшил пальто без мерки* — тегүче пальтоны үлчәмичә текте; *мерка из бумаги* — кәгазь үлчәү; 2. *перен.* үлчәү, критерий; *с одной меркой нельзя подходить к явлениям разных эпох* — төрле эпохалардагы күренешләрне бер үлчәү белән үлчәргә ярамый.

**МЕРКАНТИЛИ'ЗМ** *м. мн.* нет —1. *истор. экон.* меркантилизм (15—18 йөзләрдә Көнбатыш Европада хөкем сөргән, җәмгыять байлыгының нигезе — акча дигән принципка корылган һәм тышкы сәүдәдә актив баланс булдыру юлы белән ил эчендә акча туплауга юнәлдерелгән экономик теория һәм экономик политика системасы); 2. *книж. неодобр. перен.* торгашлык, исәпхисапта ваклык, үз файдаң өчен генә тырышу.

**МЕРКАНТИЛИ'СТ** *м. истор. экон.* — меркантилист (меркантилизмны яклаучы, меркантилизм тарафдары).

**МИНИМАЛИ'СТСКИЙ** *книж. неодобр.*— минималистлар...-ы; минималистларча...; *минималистская идеология* — минималистлар идеологиясе.

**МИНИМА'ЛЬНО** *нареч. книж.*—иң азында, ким дигәндә, иң аз дигәндә, иң азы, минимум; *на это нужно минимально тысячу рублей* — моңа аз дигәндә (минимум) мең сум кирәк.

**МИНИМА'ЛЬНЫЙ** — минимум, иң аз, иң кечкенә, иң кыска; *минимальный срок* — иң аз срок, иң кыска срок.

**МИ'НИМУМ** *м. книж.*— 1. минимум, иң аз, иң азы, иң ким, иң киме; *минимум атмосферного давления* — атмосфера басымының минимумы (иң киме); 2. *в знач. нареч.* минимум, аз дигәндә, иң азы; *эта работа потребует минимум два дня* — бу эшкә минимум (аз дигәндә) ике көн кирәк булачак; 3. *в знач. неизм. прил.* минимум; *программа-минимум* — программа-минимум (политик партияләр программасының беренче чиратта хәл ителергә тиеш булган иң мөһим бурычлары һәм таләпләре). ◇ Технический минимум — техник минимум, техминимум (техниканың берәр өлкәсендә эшләүчеләр өчен иң кирәкле техник белемнәренең минимумы). Агрономический минимум — агрономик минимум (авыл хуҗалыгы өчен иң кирәк булган чараларның минимумы). Прожиточный минимум — көнкүреш минимумы (тормыш алып бару өчен кирәкле средстволарның минимумы).

**МИНИ'РОВАТЬ** *сов. и несов. спец.*— мина кую, мина салу, миналау.

**МИНИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд. спец.*— мина куелу, мина салыну, миналану.

**МИНИСТЕ'РСКИЙ** — 1. министр...-ы; министрлык...-ы; *министерский пост* — министрлык посты; 2. *полит.* министрлар ...-ы; *министерский кризис* — министрлар кризисы (капиталистик илләрдә политик хәлнең кискенләшүе нәтиҗәсендә министрлар кабинетының алмашынуы).

**МИНИСТЕ'РСТВО** *ср.* — министрлык; *Министерство просвещения* — Мәгариф министрлыгы.

**МИНИСТЕ'РША** *ж. простореч. устар.*— министр хатыны.

**МИНИ'СТР** *м.* — министр; *министр финансов* — финанс министры.

**МИННЕЗИ'НГЕР** *м. истор. лит.*— миннезингер (урта гасырларда немец шагыйрь-җырчысы).

**МИ'ННЫЙ** *воен.* — мина...-ы; *минный взрыв* — мина шартлавы; *минное поле* — мина кыры.

**МИНОВА'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж. устар.*: **по минованин** — үтү белән, үткәч, узгач; **за минованием** — үтү аркасында, үтү сәбәпле.

**МИНОВА'ТЬ** *сов.* и *несов.*— 1. үтеп китү; читләтеп үтеп китү, кермичә үтеп китү; *миновать деревню* — 1) авылдан үтеп китү; 2) авылны читләтеп үтеп китү, авылга кермичә үтеп китү; 2. *перен. книж.* тимәү, кагылмау, тимичә үтү, тимичә үтеп китү; 3. котылу, котылып калу; *они едва миновали гибели* — алар һәлакәттән чак котылып калдылар; 4. үтү, үтеп китү, узу, бетү; *лето миновало* — җәй үтте; *опасность миновала* — куркыныч үтте. ◇ Минуя *что книж.*— тукталмыйча, төшереп калдырып; *я расскажу вам вкратце, минуя подробности* — мин сезгә, вак-төякләргә тукталмыйча, кыскача гына сөйләп бирермен.

**МИНО'ГА** *ж.*— минога (түгәрәк авызлылар семьялыгыннан суалчансыман яки елансыман балык).

**МИНОИСКА'ТЕЛЬ** I *м.*— мина эзләү аппараты (дошман тарафыннан куелган миналарны эзли торган аппарат).

**МИНОИСКА'ТЕЛЬ** II *м.*— мина эзләүче (дошман тарафыннан куелган миналарны эзләүче белгеч-сапёр).

**МИНОМЁТ** *м. воен. мор.* — миномёт (мина ату коралы).

**МИНОМЁТНЫЙ** *воен. мор.* — миномёт ...-ы; *миномётная рота* — миномёт ротасы.

**МИНОНО'СЕЦ** *м. мор.*— миноносец (миналар белән атака ясау өчен файдаланыла торган тиз йөрешле хәрби судно).

**МИНО'Р** *м.*— 1. *муз.* минор, моңлы көй, кайгылы көй (музыка лады); 2. *перен. разг. фам.* күңелсезлек, төшенке настроение; *быть в миноре* — төшенке настроениедә булу.

**МИНО'РКА** *ж.* — минорка (тавык токымы).

**МИНО'РНЫЙ** *муз.*— 1. минорлы; минор ...-ы; *минорная гамма* — минорлы гамма; 2. *перен.* күңелсез, кәефсез, төшенке; *минорное настроение*—төшенке настроение.

**МИНУ'ВШЕЕ** *ср. мн.* нет, *в знач. сущ.*— үткәннәр, баштан үткәннәр.

**МИНУ'ВШИЙ** *книж.*— узган, үткән; *минувшие годы* — үткән еллар.

**МИ'НУС** *м.*— 1. *мат.* минус (алу билгесе); 2. *перен. разг.* җитешсезлек, кимчелек;

*квартира имеет много минусов* — квартираның бик күп җитешсезлекләре бар.

**МИНУ'ТА** *ж.* — минут (1. вакыт берәмлеге; 2. *спец.* почмак үлчәвендә градусның алтмыштан бер өлеше; 3. бик кыска вакыт, аз гына вакыт). ◇ **Одну минуту или одна минута!** *разг.* — бер генә минут көтегез, аз гына көтегез! **Минуту внимания!** *разг.* — бер генә минутка игътибарыгызны (нәрсәгә булса да) туплагыз!

**МИНУ'ТНЫЙ** — 1. *спец.* минут...-ы; *минутная стрелка часов* — сәгатьнең минут стрелкасы; 2. бер минутлык; *минутный промежуток* — бер минутлык ара; *минутное дело* — бер минутлык эш; 3. *разг.* кыска вакытлы; *минутная встреча* — кыска вакытлы очрашу.

**МИНУ'ТЬ** *сов. книж.* — 1. үтү, үтеп китү; *минуло ещё два дня* — тагын ике көн үтте; 2. булу, тулу, тулып үтү; *ему минуло шестнадцать лет* — аңа уналты яшь тулып үтте.

**МИНЬО'Н** *м. мн.* нет — миньон (1. *тип.* бик вак шрифт; 2. шоколадның бер сорты; 3. *устар.* танец төре).

**МИОКАРДИ'Т** *м. мед.* — миокардит (йөрәк мускулларының ялкынсынуы).

**МИР I** *м.* — 1. *только ед.* галәм, дөнья; *трудящиеся всего мира* — бөтен дөнья хезмәт ияләре; *животный мир* — хайваннар дөньясы; *растительный мир* — үсемлекләр дөньясы; 2. *собир.* халык, кешелек дөньясы; *взоры всего мира обращены на нас* — бөтен кешелек дөньясының күзләре безгә текәлгән; 3. *истор.* җыен; *созвать мир* — җыен җыю. ◇ **С миру по нитке — голому рубашка** — ил төкерсә, күл булыр. **Пустить по миру** *разг.* — бөлдерү, бөлгенлеккә төшерү, хәерчелеккә дучар итү. **Пойти по миру** *разг.* — хәер сорашырга китү. **Ходить по миру** *разг.* — хәер сорашу. **Не от мира сего** *перен. разг.* — алла бәндәсе (реаль тормышка яраксыз кеше, хыялга бирелүчән кеше). **Всем миром** *разг.* — бергәләп, ил белән.

**МИР II** *м. мн.* нет — 1. татулык, дуслык; иминлек; *жить в мире* — тату яшәү; 2. тынычлык; *борьба за мир* — тынычлык өчен көрәш; *мир победит войну* — тынычлык сугышны җиңәчәк; 3. солых, тынычлык договоры, килешү, килешү договоры; *заключить мир* — килешү, солых ясау, солых договоры төзү; *Брестский мир* — Брест килешүе.

**МИРАБЕ'ЛЬ** *ж. мн.* нет — мирабель (сары төстәге вак слива һәм шуның агачы).

**МИРАБЕ'ЛЬНЫЙ** — мирабель...-ы; *мирабельное варенье* — мирабель вареньесы.

**МИРА'Ж** *м.* — 1. мираж (атмосфераның төрле катлауларының төрле дәрәҗәдә җылынулары нәтиҗәсендә ачык һәм тын һавада була торган оптик күренеш; бу вакытта горизонт артындагы күренми торган әйберләр һавада чагылып күренәләр); 2. *перен.* хыял, иллюзия; *мираж славы* — дан хыялы; *мираж любви* — мәхәббәт хыялы.

**МИРВО'ЛИТЬ** *несов. просторечь.* — ирек кую, ирек бирү, артык яклау, иркәләү, үзсендерү, узындыру.

**МИРИА'ДЫ** *мн. книж.* — очсыз-кырыйсыз күп, исәпсез күп, сансыз күп; *мириады звёзд* — исәпсез күп йолдызлар.

**МИ'РИКА** *ж. бот.* — аю табаны (үсемлек).

**МИРИ'ТЬ** *несов.* — татулаштыру, килештерү.

**МИРИ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. *(прекращать ссору)* татулашу, килешү; 2. *(не противодействовать)* күнү, килешү, риза булу, каршы килмәү.

**МИ'РНО** *нареч.* — татулык белән, килешеп, тыныч.

**МИ'РНЫЙ** — 1. тыныч, тынычлык сөюче, иминлек сөюче, тату; *мирный народ* — тынычлык сөюче халык; 2. дусларча..., дуслык...-ы; *мирные отношения* — дусларча мөнәсәбәтләр, дуслык мөнәсәбәтләре; 3. *книж. поэт.* тыныч; *мирная жизнь* — тыныч тормыш; *мирный труд* — тыныч хезмәт; 4. *полит.* килешү...-ы; килешү турындагы; *мирный договор* — килешү договоры; *мирные переговоры* — килешү турындагы сөйләшүләр.

**МИ'РО** *ср. мн.* нет, *церк.* — миро (христианнарда дини йолалар вакытында сөртелә торган хуш исле май). ◇ **Одним миром мазаны** *просторечь. шутл.* — бер чыбыктан сөрелгәннәр.

**МИРОВА'Я** *ж. мн.* нет, *разг. устар.* — килешү; *пойти на мировую* — килешүгә бару; *предлагать мировую* — килешү тәкъдим итү.

**МИРОВОЗЗРЕ'НИЕ** *ср. книж.* — дөньяга караш (табигатькә һәм кешелек җәмгыятенә карашлар җыелмасы); *марксистско-ленинское мировоззрение* — дөньяга марксистик-ленинчыл караш.

**МИРОВОЗЗРЕ'НЧЕСКИЙ** *книж.* — дөньяга караш...-ы; *мировоззренческий принцип* — дөньяга караш принцибы.

**МИРОВО'Й I** — 1. бөтендөнья...-ы; бөтен дөньяга таралган, дөнья күләмендәге; *мировой пролетариат* — бөтен дөнья пролетариаты; *мировая слава* — бөтен дөньяга таралган дан; 2. халыкара; *мировая политика* — халыкара политика; 3. *перен. шутл. просторечь.* бик яхшы, бик шәп, бик әйбәт; *обед сегодня — мировой!* — бүген аш бик яхшы!

**МИРОВО'Й II** *юр.*: **мировой судья** *дореvол.* — мировой судья (революциягә кадәр вак-төяк эшләрне караучы, тикшерүче судья).

**МИРОЕ'Д** *м. просторечь.* и *публиц.* — эксплуататор, кулак, байгура (кеше көченнән файдаланучы, халык җилкәсен кимерүче).

**МИРОЕ'ДСТВО** *ср. мн.* нет, *просторечь.* и *публиц.* — кеше көченнән файдалану, халык җилкәсен кимерү.

**МИРОЗДА'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — к. вселенная.

**МИРО'К** *м.* — 1. халык, дөнья; *артистический мирок* — артист халкы, артистлар дөньясы; 2. тирә-юнь; *он проснулся и обвёл*

*глазами свой маленький мирок* — ул уянды да тирә-юненә күз йөртеп чыкты.

**МИРОЛЮБИ'ВОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— тынычлык сөючәнлек, татулык сөючәнлек; *миролюбивость характера* — характерның тынычлык сөючәнлеге.

**МИРОЛЮБИ'ВЫЙ** *книж.*— 1. тынычлык сөюче; татулык сөюче, тынычлык сөючән; *миролюбивый народ* — тынычлык сөюче халык; 2. тынычлык...-ы; дуслык...-ы; татулык...-ы; *миролюбивая политика* — тынычлык политикасы.

**МИРОЛЮ'БИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.*— тынычлык сөю, татулык ярату, тынычлыкка омтылу, тынычлык сакларга тырышу, дуслыкка омтылу, татулыкка омтылу, килешүгә омтылу.

**МИРО'Н** *м. зоол.*— мыекчыл (карплар семьялыгыннан булган елга балыгы).

**МИРОНАРУШИ'ТЕЛЬ** *м. офиц.*— тынычлык бозучы.

**МИРООЩУЩЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.*— тирә-юньгә мөнәсәбәт, чынбарлыкны сизү, чынбарлыкны тою.

**МИРОПОНИМА'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.*— дөньяны аңлау, тирә-юньне аңлау, чынбарлыкны аңлау.

**МИРОСОЗЕРЦА'НИЕ** *ср. книж.*— к. мировоззрение.

**МИРОСОЗЕРЦА'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.*— к. мировоззренческий.

**МИРОТВО'РЕЦ** *м. книж.*— тынычлык саклаучы, тынычлык урнаштыручы.

**МИРОТВО'РНЫЙ** *поэт. устар.*— тынычлык саклый торган; тынычлык урнаштыра торган; тынычлык саклаучан; тынычландыручы; тынычлык китерә торган.

**МИРОТВО'РЧЕСКИЙ** *книж. ритор.*— тынычлык саклау...-ы; тынычлык урнаштыру...-ы; *миротворческая деятельность*— тынычлык саклау эшчәнлеге, тынычлык урнаштыру эшчәнлеге.

**МИ'РРА** *ж. бот.*— мирра (1. исле сумала; 2. шул сумала алына торган үсемлек).

**МИРСКО'Й** — 1. *устар.* халык...-ы; *мирская молва*—халык сүзе; *мирская сходка*— халык җыены; 2. дөнья...-ы; *мирская суета* — дөнья мәшәкатьләре.

**МИРТ** *м.* и **МИ'РТА** *ж. бот.*— мирт (мәңге яшел куак үсемлек).

**МИ'СКА** *ж.*— миски (савыт).

**МИ'СОЧНЫЙ** — миски...-ы; *мисочная крышка* — миски капкачы.

**МИСС** *ж. нескл.*— туташ (Англия һәм Америкада кыз кешегә эндәшкәндә фамилия яки исем алдыннан әйтелә торган сүз).

**МИССИОНЕ'Р** *м.*— миссионер (дине башка булган халыкларга икенче бер дин тарату өчен җибәрелгән кеше).

**МИССИОНЕ'РКА** *ж.*— к. миссионер.

**МИССИОНЕ'РСКИЙ** — миссионерлар...-ы; миссионер...-ы; *миссионерская школа* — миссионерлар мәктәбе.

**МИССИОНЕ'РСТВО** *ср. мн.* нет — миссионерлык.

**МИ'ССИС** *ж. нескл.*— ханым (Англия һәм Америкада хатын кешегә хөрмәтләп эндәшү сүзе).

**МИ'ССИЯ** *ж.*— миссия (1. *книж.* тапшырылган эш, тапшырылган йомыш; 2. *только ед. книж.* нинди дә булса бер кешенең яки җәмгыять группасының тарихи роле; 3. *дипл.* икенче дәрәҗәдәге дипломатик вәкиллек; 4. *разг.* шул вәкиллек урнашкан бина; 5. *дипл.* нинди дә булса максат белән икенче бер дәүләткә җибәрелгән дипломатик делегация; 6. миссионерлар оешмасы).

**МИ'СТЕР** *м.*— мистер, әфәнде (Англия һәм Америкада ир кешегә эндәшү сүзе).

**МИСТЕ'РИЯ** *ж. книж.*— мистерия (1. *истор.* антик халыкларда һәм борынгы көнчыгыш халыкларында теге яки бу алланы зурлау йөзеннән үтәлә торган дини гореф-гадәтләр системасы; 2. *истор. лит.* урта йөзләрдә библия темаларына нигезләп язылган дини драма).

**МИ'СТИК** *м.*— мистик (мистицизмга бирелгән кеше, дини мистик теория тарафдары).

**МИ'СТИКА** *ж. мн.* нет — мистика (1. *книж.* табигатьтән тыш илаһи көчләр бар, дип өйрәтә торган дини-философик тәгълимат; 2. *перен. разг. ирон.* серле, аңлаешсыз нәрсә).

**МИСТИФИКА'ТОР** *м. книж.*— мистификатор, мистификация белән шөгыльләнүче.

**МИСТИФИКА'ЦИЯ** *ж. книж.*— мистификация (берәр төрле максат белән юри алдау, саташтыру).

**МИСТИФИЦИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. книж.*— юри алдау, саташтыру.

**МИСТИФИЦИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд. книж.*— алдану, саташтырылу.

**МИСТИЦИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *книж.*— мистицизм (табигатьтән тыш илаһи көчләр барлыгына ышану, мистикага бирелү, мистикага ышану).

**МИСТИ'ЧЕСКИЙ** — 1. *книж.* мистик, мистицизм ...-ы; *мистическая теория* — мистицизм теориясе; *мистические переживания* — мистик кичерешләр; 2. мистиклар ...-ы; *мистическая секта* — мистиклар сектасы; 3. *разг. ирон.* мистик ...; аңлаешсыз, серле; *мистические бредни* — мистик саташулар.

**МИСТИ'ЧНЫЙ** *разг. ирон.*— к. мистический 3.

**МИ'ТЕНКИ** *мн.*—бармакчасыз перчатка.

**МИ'ТИНГ** *м.*— митинг.

**МИТИНГОВА'ТЬ** *несов. разг.*—1. митинг үткәрү; митинг җыю; митингта булу, митингта катнашу; 2. *перен. неодобр.* күп сөйләү, сүз боткасы пешерү, күп әңгәмә сату.

**МИТИНГО'ВЩИНА** *ж. мн.* нет, *разг. неодобр.*— к. митинговать 2.

**МИТКА'ЛЕВЫЙ** — миткаль...; *миткалевая ткань* — миткаль тукыма.

**МИТКА'ЛЬ** *м. мн.* нет — миткаль (иң гади, арзанлы тукыма, бәз).

**МИТРОПОЛИ'Т** *м.*— митрополит (православныйларда иң югары дини звание).

**МИФ** *м.*— миф (1. *истор. лит.* дөнья-

ның барлыкка килүе, табигать күренешләре, аллалар яки геройлар турында борынгы халык әкиятләре; 2. *перен.* фантастик әйбер; уйдырма, хыялый әйбер, чынбарлыкка туры килми торган караш; *Советская Армия разбила миф о непобедимости фашизма* — Совет Армиясе фашизмның җиңелмәслеге турындагы мифны юкка чыгарды).

**МИФИ'ЧЕСКИЙ** — 1. *книж.* мифик; *мифический сюжет* — мифик сюжет; 2. мифик; уйдырма, чынлыкта булмаган; *мифическое богатство* — уйдырма байлык.

**МИФИ'ЧНЫЙ** — к. мифический 2.

**МИФО'ЛОГ** *м.* — мифолог, мифология белгече.

**МИФОЛОГИ'ЧЕСКИЙ** — мифологик; *мифологическое сказание* — мифологик хикәя.

**МИФОЛО'ГИЯ** *ж.* — мифология (1. мифлар системасы, мифлар җыелмасы; 2. *только ед.* мифлар турындагы фән).

**МИ'ЧМАН** *м. мор.* — мичман (1. СССР хәрби диңгез көчләренең кече начальниклары составында өлкән дәрәҗә; 2. патша Россиясе флотында һәм кайбер чит ил флотларында диңгез флоты офицерларының беренче чины).

**МИЧУ'РИНЕЦ** *м.* — мичуринчы (авыл хуҗалыгында һәм биологиядә Мичурин методларын кулланучы).

**МИШАРИ'** — мишәрләр.

**МИШЕ'НЬ** *ж.* — мишень (1. *спец.* ату күнегүләре ясау өчен куелган яки билгеләнгән цель; 2. *перен. книж.* мәсхәрәләү яки эзәрлекләү өчен объект итеп алынган предмет яки кеше).

**МИ'ШКА** *м. разг.* — 1. *фам.* аю; 2. *детск.* мишка (аю баласына охшатып ясалган балалар уенчыгы).

**МИШУРА'** *ж. мн.* нет — 1. *спец.* ука; 2. *перен. неодобр.* ялтыравык, ялган ялтыравык.

**МИШУ'РНЫЙ** — 1. *спец.* ука...-ы; *мишурное производство* — ука производствосы; 2. *перен.* ялган; ясалма; *мишурный блеск* — ялган ялтыравык.

**МЛАДЕ'НЕЦ** *м. книж.* — 1. *поэт.* сабый, нарасый, яшь бала; 2. *перен.* тәҗрибәсез-кеше, булдыксыз кеше; *политические младенцы* — политик тәҗрибәсез кешеләр.

**МЛАДЕ'НЧЕСКИЙ** *книж.* — 1. сабыйлык ...-ы; *младенческий возраст* — сабыйлык яше; 2. *перен. пренебр.* көчсез, сабыйларча; *младенческие потуги* — сабыйларча көчәнүләр (көчәнеп маташулар).

**МЛАДЕ'НЧЕСТВО** *ср. мн.* нет, *книж.* — сабыйлык, сабый чак, бала чак.

**МЛАДО'Й** — к. молодой 1.

**МЛА'ДОСТЬ** *ж. мн.* нет — к. молодость.

**МЛА'ДШИЙ** — 1. яшь, кече; *младшее поколение* — яшь буын, кече буын; *младший лейтенант* — кече лейтенант; 2. иң яшь, иң кече, төпчек; *младший в семье* — семьяда иң яшь кеше. ◇ **Младший брат** — эне. **Младшая сестра** — сеңел.

**МЛЕКОПИТА'ЮЩИЕ** *мн. зоол.* — имезүчеләр (имезүче хайваннар).

**МЛЕТЬ** *несов.* — 1. ою; *ноги млеют на стуже* — салкыннан аяклар оеый; 2. *книж.* катып калу, тынсыз калу; *млеть от страха* — куркудан катып калу; 3. изрәү, хәлдән таю; *млеть от восторга* — шатлыктан изрәү.

**МЛЕ'ЧНИК** *м. бот.* — сөтлегән.

**МЛЕ'ЧНЫЙ** *бот.* — сөтсыман; *млечный сок* — сөтсыман сок (үсемлек согы). ◇ Млечный Путь *астр.* — Киек Каз Юлы (күк йөзендә йолдызлар тупланышыннан гыйбарәт булган ак полоса).

**МНЕМО'НИК** *м. спец.* — мнемоник (мнемоник методлар нигезендә хәтерне ныгыту буенча белгеч).

**МНЕМО'НИКА** *ж. мн.* нет — мнемоника (мөмкин кадәр күбрәк фактларны, мәгълүматларны истә калдырырга ярдәм итә торган алымнар һәм кагыйдәләр җыелмасы).

**МНЕМОНИ'ЧЕСКИЙ** — мнемоник; *мнемонические приёмы* — мнемоник алымнар.

**МНЕМОТЕ'ХНИКА** *ж. мн.* нет, *спец.* — к. мнемоника.

**МНЕ'НИЕ** *ср.* — уй, фикер; *общественное мнение* — җәмәгатьчелек фикере.

**МНИ'МОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — 1. уйдырма булу, уйдырмалык, ялган булу; *мнимость болезни* — авыруның ялган булуы; 2. *мат.* уйланма булу; *мнимость величины* — зурлыкның уйланма булуы.

**МНИ'МЫЙ** *книж.* — 1. уйланма, чынында булмаган; буш, ялган, уйдырма; *мнимая опасность* — уйланма (чынында булмаган) куркыныч; *мнимый больной* — ялган авыру; *мнимые знания* — буш белемнәр, уйдырма белемнәр; 2. *мат.* уйланма (сан).

**МНИ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — шикләнүчәнлек, юктан шикләнү, шомлану.

**МНИ'ТЕЛЬНЫЙ** — юктан шикләнүчән, шомланучан, шикләнеп (юктан) куркучан; *мнительный человек* — юктан шикләнүчән кеше.

**МНИТЬ** *несов.* — 1. *книж. устар.* уйлау, исәпләү; өметләнү; 2. *ирон. неодобр.* үзен зурга санау, үзен зурга кую; *много о себе мнит* — үзен бик зурга куя.

**МНО'ГАЖДЫ, МНОГА'ЖДЫ** *нареч. старин., теперь разг. шутл.* — күп тапкыр, еш, берничә мәртәбә.

**МНО'ГИЕ** *только мн.* — 1. күп; *у многих наших рек правый берег выше левого* — безнең күп елгаларыбызның уң яралары сул ярларыннан биегрәк; 2. *в знач. сущ.* күпләр, күп кешеләр; *многие так думают* — күпләр шулай уйлыйлар, күп кешеләр шулай уйлыйлар. ◇ **Многие лéта** и **многи лéта** *книж. устар.* — озын гомер сезгә; озак яшәгез; күп яшәгез.

**МНО'ГО** *нареч.* — күп. ◇ **Много лучше, на много лучше** — күп тапкыр яхшырак. **Ни много, ни мало** *разг.* — нәкъ, төгәл; *ни много, ни мало сто рублей* — нәкъ йөз сум. **Много-много** *разг.* — иң күбендә, күп дигәндә.

**МНОГОБО'ЖИЕ** *ср. мн.* нет — күп аллага ышану.

**МНОГОБО'РЕЦ** *м. спорт.*— многоборец (многоборье белән шөгыльләнүче спортчы).

**МНОГОБО'РЬЕ** *ср. мн.* нет, *спорт.* — многоборье (берничә төр күнекмәне, мәсәлән, йөгерүне, йөгергәндә берәр киртә аркылы чыгуны, киң канау аркылы сикерүне һ. б. эченә алган спорт ярышы).

**МНОГОБРА'ЧИЕ** *ср. мн.* нет—1. күп хатын (ир) белән тору; 2. *бот.* бер өйлелек.

**МНОГОБРА'ЧНЫЙ** —1. күп хатынлы (ирле); 2. *бот.* бер өйле (үс.).

**МНОГОВА'ТО** *нареч. разг. фам.*— күбрәк, артыграк.

**МНОГОВЕКОВО'Й** — күп гасырларга сузылган, күп гасырлы; *многовековая история человечества* — кешелек дөньясының күп гасырларга сузылган тарихы.

**МНОГОВЛА'СТИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.*— күп властьлылык.

**МНОГОВО'ДНЫЙ** —1. күп сулы; *многоводная река* — күп сулы елга; 2. су ташу ...-ы; *многоводная пора* — су ташу вакыты.

**МНОГОВО'ДЬЕ** *ср. мн.* нет —1. *(весенний разлив)* су ташу; 2. *(излишек воды)* су күплек.

**МНОГОГОВОРЯ'ЩИЙ** *книж.*—күп нәрсәне ачыклый торган; күп нәрсәне белдерә торган; *многоговорящее показание* — күп нәрсәне ачыклый торган күрсәтмә.

**МНОГОГОЛО'ВЫЙ** *книж.*— күп башлы; *многоголовая гидра* — күп башлы аждаһа (гидра).

**МНОГОГОЛО'СИЕ** *ср. мн.* нет, *муз.* — күп тавышлылык, төрле тавышлылык.

**МНОГОГРА'ННИК** *м. мат.*— күпкырлык.

**МНОГОГРА'ННЫЙ** *книж.*—1. *мат.* күпкырлы; *многогранный угол* — күпкырлы почмак; 2. *перен.* киң белемле, бик зирәк, күпьяклы, күпкырлы; *многогранный человек* — киң белемле кеше; *многогранный талант* — күпьяклы талант, күпкырлы талант.

**МНОГОДЕ'ЛЬНЫЙ** *разг.*— күп хезмәт сорый торган; *многодельная работа* — күп хезмәт сорый торган эш.

**МНОГОДЕ'ТНЫЙ** — күп балалы; *многодетная мать* — күп балалы ана.

**МНО'ГОЕ** *ср. мн.* нет, *в знач. сущ.*— күп әйберләр, күп нәрсәләр, күп мәсьәләләр; *нам надо о многом переговорить* — безгә күп нәрсәләр турында сөйләшеп алырга кирәк; *во многом он оказался прав* — күп мәсьәләләрдә ул хаклы булып чыкты.

**МНОГОЖЁНСТВО** *ср. мн.* нет, *этнол.*— күп хатынлылык, күп хатын белән тору.

**МНОГОЗЕМЕ'ЛЬЕ** *ср. мн.* нет, *социал. экон.*— күп җирлелек.

**МНОГОЗЕМЕ'ЛЬНЫЙ** *социал. экон.* — күп җирле; җир участогы зур булган; *многоземельные районы* — җир участогы зур булган районнар; *многоземельные совхозы* — күп җирле совхозлар.

**МНОГОЗНА'ЙКА** *м.* и *ж. разг. ирон.*— к. всезнайка.

**МНОГОЗНА'ЙСТВО** *ср. мн.* нет, *разг. ирон.*— к. всезнайство.

**МНОГОЗНАМЕНА'ТЕЛЬНЫЙ** *книж. устар.*— зур әһәмиятле; *многознаменательное событие* — зур әһ миятле вакыйга.

**МНОГОЗНАЧИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.*—1. зур әһәмияткә ия булган; зур әһәмияте булган; зур әһәмиятле; кирәкле; *многозначительная встреча*—зур әһәмияте булган (кирәкле) очрашу; 2. мәгънәле; *многозначительный взгляд* — мәгънәле караш.

**МНОГОЗНА'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*—1. *мат.* күп кыйммәтлелек, күп билгелелек (цифр билгеләре күп булучылык; күп цифрлылык); 2. *лингв.* күп мәгънәлелек.

**МНОГОЗНА'ЧНЫЙ** *книж.*—1. күпкыйммәтле, күбурынлы; *многозначное число* — күбурынлы сан; 2. *лингв.* күп мәгънәле; *многозначное слово* — күп мәгънәле сүз.

**МНОГОКЛЕ'ТОЧНЫЙ** *биол.*— күп күзәнәкле; *многоклеточное строение тела* — җисемнең күп күзәнәкле төзелештә булуы.

**МНОГОКРА'СОЧНЫЙ** *тип.*— күп буяулы; *многокрасочное воспроизведение* —күп буяулы күчермә.

**МНОГОКРА'ТНОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. *книж.* кабатлану; кабатланган булу; *многократность требований* — таләпләрнең кабатлануы; 2. *грам.* кабатланучанлык.

**МНОГОКРА'ТНЫЙ** *книж.*—1. кабат-кабат, кат-кат, күп тапкыр, берничә кат; *многократные напоминания* — күп тапкыр искәртүләр; 2. *мат.* күп кабатлы, күп саннарга төгәл бүленә торган (сан). ◇ Многократный вид *грам.* — кабатлаулы фигыль күренеше.

**МНОГОЛА'МПОВЫЙ** *радио* — күп лампалы; *многоламповый приёмник* — күп лампалы алгыч.

**МНОГОЛЕ'ТИЕ** *ср. книж. устар.*— озын гомер.

**МНОГОЛЕ'ТНИЙ** — 1. күп яшәүче, күп яшәгән; *многолетний старец*—күп яшәгән карт; 2. күпьеллык...; *многолетний труд* — күпьеллык хезмәт; *многолетнее растение* — күпьеллык үсемлек.

**МНОГОЛЕ'ТНИК** *м. бот.* — күпьеллык үсемлек.

**МНОГОЛЮ'ДНОСТЬ** *ж мн.* нет— халык күплек, халыкның күплеге, халыкның күп булуы; *многолюдность собрания* — җыелышта халыкның күп булуы.

**МНОГОЛЮ'ДНЫЙ** — 1. күп кешеле, күп халыклы; халкы күп; *многолюдный город*— күп халыклы шәһәр; 2. күп кеше катнашкан; *многолюдное собрание* — күп кеше катнашкан җыелыш.

**МНОГОЛЮ'ДСТВО** *ср. мн.* нет — күп кеше, күп халык; *в многолюдстве я потерян, сам не свой* (Грибоедов) — күп халык арасында, үземне кая куярга белмичә, югалып калдым.

**МНОГОМЕ'СТНЫЙ** *спец.*— күп урынлы; *многоместный самолёт* — күп урынлы самолёт.

**МНОГОМЕТРО'ВЫЙ** *спец.*— күп метрлы, озын; *многометровый фильм* — озын фильм.

**МНОГОМИЛЛИО'ННЫЙ** *книж.* — күп миллионлы; *многомиллионная крестьянская масса* — күп миллионлы крестьяннар массасы.

**МНОГОМУ'ЖИЕ** *ср. мн.* нет, *этнол.*— күп ирлелек, күп ир белән тору.

**МНОГОНАЦИОНА'ЛЬНЫЙ** — күп миллэтле.

**МНОГОНАЧА'ЛИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.*— к. многовластие.

**МНОГОНО'ЖКА** *ж. зоол.*— күбаяк (күбаяклылар семьялыгыннан булган хайван).

**МНОГО'НЬКО** *нареч. просторец. фам.*— шактый күп, артык күп.

**МНОГООБЕЩА'ЮЩИЙ** *книж.*— өметле; *многообещающий талант*— өметле талант; *многообещающий ученик* — өметле укучы.

**МНОГООБРА'ЗИЕ** *ед. мн.* нет, *книж.*— күп төрлелек, күпьяклылык.

**МНОГООБРА'ЗНЫЙ** — күп төрле, төрле-төрле, күпьяклы; *многообразные явления*— күп төрле күренешләр.

**МНОГОПО'ЛЬЕ** *ср. мн.* нет, *с.-х.*— күп басу, күп кырлылык, күп басулылык.

**МНОГОПО'ЛЬНЫЙ** *с.-х.*— күп басу...-ы; күп басулы; *многопольный севооборот* — күп басулы чәчү әйләнеше.

**МНОГОРАЗЛИ'ЧНЫЙ** *книж. устар.*— төрле-төрле, күп төрле.

**МНОГОРЕ'ЧИВЫЙ** *книж. неодобр.* — озын сөйләүчән, күп сөйләүчән, сөйләшергә яратучан, күп сүзле.

**МНОГОСЕМЕ'ЙНЫЙ** — зур семьялы, күп балалы.

**МНОГОСИ'ЛЬНЫЙ** *тех.* — күп җегәрле; *многосильный автомобиль* — күп җегәрле автомобиль.

**МНОГОСЛО'ВИЕ** *ср. мн.* нет — күп сүзлелек.

**МНОГОСЛО'ВНЫЙ** — күп сүзле; *многословный человек* — күп сүзле кеше.

**МНОГОСЛО'ЖНОСТЬ** I *ж. мн.* нет, *грам. лит.*— күп иҗеклелек.

**МНОГОСЛО'ЖНОСТЬ** II *ж. мн.* нет, *книж.* — бик катлаулылык.

**МНОГОСЛО'ЖНЫЙ** I *грам. лит.*— күп иҗекле; *многосложное слово* — күп иҗекле сүз.

**МНОГОСЛО'ЖНЫЙ** II *книж.*— бик катлаулы, читен.

**МНОГОСЛО'ЙНЫЙ** *книж. спец.* — күп катламлы; күп катламнардан тора торган; *многослойные горные породы* — күп катламлы тау токымнары.

**МНОГОСОСТА'ВНЫЙ** *книж. спец.*—күп составлы; *многосоставный раствор* — күп составлы эремә.

**МНОГОСТАНО'ЧНИК** *м.*— күп станокта эшләүче (бер үк вакытта күп станокта эш алып баручы алдынгы эшче).

**МНОГОСТО'ПНЫЙ** *лит.*— күп стопалы; күп стопадан торган; *многостопный ямб*— күп стопалы ямб.

**МНОГОСТОРО'ННИЙ** *книж.*—1. *только полн. ф-мы, мат.* күпьяклы; *многосторонняя призма* —күпьяклы призма; 2. *спец.* күпьяклы, катнашучылары күп булган; *многосторонний договор* — күпьяклы договор, катнашучылары күп булган договор; 3. *перен.* күп нәрсәдән хәбәрдар, күп нәрсә белән кызыксына торган; *он—многосторонний человек* — ул—күп нәрсәдән хәбәрдар кеше, күп нәрсә белән кызыксына торган кеше.

**МНОГОСТРАДА'ЛЬНЫЙ** *книж. ритор.*— күп җәфа чиккән, күп газап күргән; күп кайгы күргән, кайгы-хәсрәтле; *многострадальный человек* — күп җәфа чиккән кеше; *многострадальная жизнь* — кайгы-хәсрәтле тормыш, кайгы-хәсрәт белән үткән тормыш.

**МНОГОСТРУ'ННЫЙ** — күп кыллы; *многострунные гусли* — күп кыллы гөслә.

**МНОГОТИРА'ЖКА** *ж.*— многотиражка (предприятиенең күп тиражлы басма газетасы).

**МНОГОТИРА'ЖНЫЙ** *тип.*— күп тиражлы; *многотиражная газета* — күп тиражлы газета.

**МНОГОТО'МНЫЙ** — күп томлы (әсәр, хезмәт).

**МНОГОТО'ЧИЕ** *ср. грам. тип.*— күп нокта.

**МНОГОТРУ'ДНЫЙ** *книж.*— бик авыр, бик кыен; *многотрудная жизнь* — бик авыр тормыш.

**МНОГОТЫ'СЯЧНЫЙ** — меңләгән; меңләгән халык катнашкан, күп меңнәрчә халык катнашкан; *многотысячная толпа* — меңләгән халык төркеме; *многотысячный митинг* — меңләгән (күп меңнәрчә) халык катнашкан митинг.

**МНОГОУВАЖА'ЕМЫЙ** — кадерле, хөрмәтле, зур хөрмәтле.

**МНОГОУГО'ЛЬНИК** *м. мат.*— күппочмак.

**МНОГОУГО'ЛЬНЫЙ** *мат.*— күппочмаклы; *многоугольная фигура* — күппочмаклы фигура.

**МНОГОФА'ЗНЫЙ** *спец.* — күп фазалы; *многофазный электрический ток* — күп фазалы электр тогы.

**МНОГОЦВЕ'ТНЫЙ** —1. күп буяулы, төрле төстәге, чуар; 2. *бот.* күп чәчәкле.

**МНОГОЧИ'СЛЕННЫЙ** — күп санлы, бик күп, күп сандагы; *многочисленный отряд*— күп санлы отряд; *многочисленные факты* — күп сандагы фактлар.

**МНОГОЧЛЕ'Н** *м. мат.*— күпбуын.

**МНОГОЧЛЕ'ННЫЙ** *книж. мат.* — күпбуынлы; *многочленная формула* — күпбуынлы формула.

**МНОГОЭТА'ЖНЫЙ** — күп этажлы; *многоэтажный дом* — күп этажлы йорт.

**МНОГОЯЗЫ'ЧНЫЙ** *книж.*— халкы күп төрле телләрдә сөйләшә торган; *многоязычная страна* — халкы күп төрле телләрдә сөйләшә торган ил.

**МНОГОЯ'РУСНЫЙ** *книж.*— күп яруслы; *многоярусный театр* — күп яруслы театр.

**МНО'ЖЕСТВЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*—күплек; *множественность форм*— формаларның күплеге.

**МНО'ЖЕСТВЕННЫЙ** *книж.*— күп, бик

күп. ◇ **Множественное число** *грам.*—күплек саны.

**МНО'ЖЕСТВО** *ср. книж.*—күп, бик күп; күплек; *множество фактов*— фактларның күплеге; бик күп фактлар.

**МНО'ЖИМОЕ** *ср. мат.*— тапкырланучы.

**МНО'ЖИТЕЛЬ** *м. мат.* — тапкырлаучы.

**МНО'ЖИТЬ** *несов.*— 1. *мат.* тапкырлау, кабатлау; 2. *книж. устар.* күбәйтү, арттыру, ишәйтү.

**МНО'ЖИТЬСЯ** *несов.*—1. *мат.* тапкырлану; 2. *книж.* күбәю, арту, ишәю.

**МОБИЛИЗАЦИО'ННЫЙ** — мобилизация ...-ы; мобилизацион; *мобилизационный план* — мобилизация планы.

**МОБИЛИЗА'ЦИЯ** *ж.*— мобилизация, мобилизацияләү (1. *воен.* гаскәрне хәрби хәлгә күчерү; 2. запастагыларны хәрби хезмәткә алу; 3. *перен. книж.* хезмәт ияләрен яки халык хуҗалыгының аерым тармакларын нинди дә булса бурычны үнышлы үтәп чыгу эшенә тарту; *необходима мобилизация всех сил страны для строительства коммунизма* — илдәге бөтен көчләрне коммунизм төзү өчен мобилизацияләргә кирәк).

**МОБИЛИЗО'ВАННОСТЬ** *ж. мн.* нет, тулы хәзерлек (берәр эшне башкарып чыгу өчен).

**МОБИЛИЗО'ВАННЫЙ** —1. мобилизацияләнгән, мобилизовать ителгән; 2. *в. знач. сущ.* мобилизацияләнгән кеше, мобилизовать ителгән кеше.

**МОБИЛИЗОВА'ТЬ** *сов.* и *несов.*— мобилизацияләү, мобилизовать итү, мобилизация ясау, көчне туплау, халыкны күтәрү; *мобилизовать широкие массы на борьбу за дальнейший подъём сельского хозяйства* — киң массаларны авыл хуҗалыгын тагын да күтәрү өчен көрәшкә тупларга (көрәшкә рухландырырга).

**МОБИЛИЗОВА'ТЬСЯ** —1. *сов.* и *несов.* мобилизацияләнү; 2. *несов. страд.* мобилизовать ителү, мобилизация ясалу.

**МОГАРЫ'Ч, МОГАРЫ'ЧНИЧАТЬ**—к. магарыч, магарычничать.

**МОГИКА'НЕ** *мн.*— могиканнар (Төньяк Америкадагы индеец кабиләләренең үлеп беткән группасы). ◇ **Последний из могикан** — соңгы могикан (бетеп бара торган бер буынның яки берәр социаль группаның соңгы кешесе).

**МОГИ'ЛА** *ж.*—1. кабер; 2. *простореч.* сер нясе. ◇ **Свести в могилу** *разг.*— үтерү, гүргә кертү. **Сойти в могилу** *ритор.*— үлү, кабергә керү. **На краю могилы** *ритор.*— үлем алдында, кабер якасында. **Унести (с собой) в могилу** *ритор.*— кабергә алып китү (берәр нәрсә турында белдермичә, серенне әйтмичә үлү).

**МОГИ'ЛЬНИК** *ж. археол.* — борынгы каберлек.

**МОГИ'ЛЬНЫЙ** — кабер ...-ы; *могильный холм* — кабер калкулыгы; *могильная тишина* — кабер тынлыгы.

**МОГИ'ЛЬЩИК** *м.*— 1. кабер казучы; 2. *перен.* кабер казучы, үлем китерүче; *пролетариат — могильщик капитализма* — пролетариат—капитализмга үлем китерүче.

**МОГУ'ЧИЙ** *ритор.*— куәтле, көчле, кодрәтле.

**МОГУ'ЩЕСТВЕННЫЙ** —куәтле, бик көчле.

**МОГУ'ЩЕСТВО** *ср. мн.* нет, *книж.*— зур көч, куәт, кодрәт.

**МОГУ'ЩИЙ** *книж.*—1. булдыра ала торган; 2. *устар.* к. могучий.

**МО'ДА** *ж.*— 1. мода (билгеле бер җәмгыятьтә билгеле бер вакыт дәвамында киемгә, туалетка карата өстенлек иткән гадәтләр һәм вкуслар җыелмасы); 2. *просторечь.* гадәт; *у меня нет моды деньгами платить* — минем акчалата түләү гадәтем юк; 3. *стат.* билге (бер группада иң күп очрый торган билге).

**МОДА'ЛЬНОСТЬ** *ж. книж. грам.*— модальлек (сөйләүченең чынбарлыкка карата үз сөйләме аша белдергән мөнәсәбәте).

**МОДА'ЛЬНЫЙ** *книж.*— модаль; *модальные слова* — модаль сүзләр (мәсәлән, гүя, бәлки, әйтерсең, ихтимал, шиксез кебек сүзләр).

**МОДЕЛИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.* — 1. скульптураны эшкәртү; 2. *спец.* модель хәзерләү, үрнәк хәзерләү, өлге хәзерләү (мәсәлән, күлмәк өлгесен).

**МОДЕЛИ'СТКА** *ж.* — моделистка (тегү промышленностенда эшләүче югары квалификацияле тегүче хатын-кыз).

**МОДЕ'ЛЬ** *ж.*— 1. *спец.* модель, үрнәк; *модель товара* — товар үрнәге; *модель платья* — күлмәк моделе; 2. *тех.* модель (берәр нәрсәнең кечерәйтеп ясалган үрнәге яки схемасы); *модель машины* — машина моделе; 3. марка, модель, тип; *автомобиль новой модели* — яңа маркалы автомобиль, яңа типтагы автомобиль; 4. *тех.* (эретеп кою эшендә кулланыла торган) калып, өлге; 5. *науч.* схема, чертёж (нинди дә булса физик күренешне яки процессны аңлату өчен геометрик чертёж, схема); *модель строения атома* — атом төзелешенең схемасы; 6. *перен.* үрнәк. ◇ **Не модель так поступать** *просторечь. фам.*— болай эшләргә ярамый, яхшы түгел.

**МОДЕЛЬЕ'Р** *м. спец.* — модельер (модельләр хәзерләү белгече).

**МОДЕ'ЛЬНЫЙ** *спец.*—1. модель ...-ы; модельләр ясау...-ы; *модельный цех* — модель цехы; 2. югары сыйфатлы, тиешле модель буенча эшләнгән (кием һәм аяк киемнәре турында гына); *модельные туфли*—тиешле модель буенча эшләнгән туфли.

**МОДЕ'ЛЬЩИК** *м. спец.*— модель ясаучы, калыпчы, калып хәзерләүче эшче.

**МОДЕРА'ТОР** *м.*— модератор (1. *муз.* клавишлы музыка коралларында тавыш көчен көйләү җайланмасы; 2. *тех.* машиналарның бару тизлеген акрынайту җайланмасы).

**МОДЕРНИЗА'ТОР** *м. книж.*— модернизатор, яңартучы, модернизацияләүче.

**МОДЕРНИЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. книж.*—яңарту, камилләштереп яңача ясау, яңалык кертү, модернизацияләү; *модернизировать технику*—техникага яңалык кертү.

**МОДЕРНИЗИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. книж.*— яңартылу, яңача ясалу, модернизацияләнү.

**МОДЕРНИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *искус.*— модернизм (XIX йөз ахырында реализмның дошманы буларак килеп чыккан, әдәбиятны һәм сәнгатьне империалистик буржуазиянең төшенкелек настроениеләренә яраклаштырырга маташучы реакцион агым).

**МОДЕРНИЗОВА'ТЬ** *сов.* и *несов. книж.*— к. модернизировать.

**МОДЕРНИЗОВА'ТЬСЯ** *сов.* и *несов. книж.*— к. модернизироваться.

**МОДЕРНИ'СТ** *м.*, **МОДЕРНИ'СТКА** *ж. искус.*— модернист, модернистка (модернизмга иярүче, модернизм тарафдары).

**МОДИ'СТКА** *ж.*— модистка (1. хатын-кыз эшләпәләре мастеры; 2. *устар.* тегүче хатын-кыз).

**МОДИФИКА'ТОР** *м. тех.*— модификатор (машинаның хәрәкәтен һәм, гомумән, эшне модификацияләү өчен җайланма).

**МОДИФИКА'ЦИЯ** *ж. книж.* — модификация (1. үзгәрү, үзгәреш, башка төргә әйләнү; үзгәртү, башка төргә әйләндерү; 2. үзгәргән әйбер, башка төргә кергән әйбер).

**МОДИФИЦИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. книж.*— үзгәртү, үзгәреш кертү (предметның асылына кагылмыйча формасын үзгәртү).

**МОДИФИЦИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. книж.* — 1. үзгәрү, модификацияләнү; 2. *страд.* үзгәртелү.

**МО'ДНИК** *м.*, **МО'ДНИЦА** *ж. разг.*— модага иярүче.

**МО'ДНИЧАТЬ** *несов. разг. фам.*—1. модага ияру, мода артыннан куу, мода буенча киенү; купшылану; 2. *перен. простореч.* кылану, назлану, чытлыклану, көязләнү.

**МО'ДНЫЙ** —1. модалар...-ы; *модный журнал* — модалар журналы; 2. модага кергән; иң соңгы мода буенча тегелгән; *модное платье* — иң соңгы мода буенча тегелгән күлмәк.

**МОДУЛИ'РОВАТЬ** *несов.*—1. *муз.* тон үзгәртү, бер тоннан икенче тонга күчү; 2. *тех.* модуляция ясау (электр тогы тирбәнешләрен үзгәртү).

**МО'ДУЛЬ** *м.*— модуль (1. *физ.* кайбер фәннәрдә коэффициентлар исеме; *модуль упругости* — эластиклык модуле; 2. *мат.* нинди дә булса бер система логарифмын табу өчен, бөтенләй башка система логарифмына тапкырларга кирәк булган сан; 3. *архит.* колонна нигезенең радиусы).

**МОДУЛЯ'ТОР** *м. кино* — модулятор (киноплёнкага тавыш язу приб ры).

**МОДУЛЯ'ЦИЯ** *ж.*— модуляция (1. *муз.* музыкада бер тоннан икенче тонга күчү; тавыш югарылыгының үзгәрүе; 2. *тех. радио* микрофонга килә торган тавышлар тәэсирендә радиотапшыруларда кулланыла торган электр тогының үзгәрүе; 3. *кино* киноплёнкага тавыш язу аркасында электрик тирбәнешләрнең үзгәреше).

**МО'ДУС** *м. науч.*— төр, төрчә. ◇ **Модус вивенди** *книж.*— нормаль мөнәсәбәт саклау шартлары (ике дәүләт яки нинди дә булса ике як арасында).

**МО'ЕЧНЫЙ** — юу...-ы; *моечная машина* — юу машинасы.

**МО'ЖЕТ, МО'ЖЕТ БЫТЬ** *ввод. сл.*—ихтимал, бәлки.

**МОЖЖЕВЕ'ЛИНА** *ж. обл.*— артыш җиләге.

**МОЖЖЕВЕ'ЛОВЫЙ** — артыш...-ы; *можжевеловый куст* — артыш куагы.

**МОЖЖЕВЕ'ЛЬНИК** *м. бот.*— артыш (агачы).

**МО'ЖНО** *в знач. сказ.*— мөмкин, ярый, була. ◇ **Как можно** — мөмкин кадәр; *как можно лучше* — мөмкин кадәр яхшырак.

**МОЗА'ИКА** *ж.* — мозаика (1. *искус.* төрле төстәге пыялалардан, вак ташлардан оештырып ясалган художестволы бизәк; сурәт; 2. *только ед. разг.* шундый бизәкләрне эшләү сәнгате; 3. төрле төстәге шакмаклардан, вак шарлардан бизәкләр, сурәтләр тезеп уйнау (балалар уены); 4. *перен. книж.* төрле элементлардан торган катлаулы, чуар катнашма).

**МОЗАИ'ЧНЫЙ** *книж.*—1. *искус.* мозаик; мозаика рәвешендәге; *мозаичный рисунок* — мозаик (мозаика рәвешендәге) рәсем; 2. *перен.* катнашма, төрле элементлардан катнашкан.

**МОЗГ** *м.*—1. *анат.* ми; 2. *анат.* желек; *костный мозг* — сөяк җелеге; 3. *перен. только мн. простореч. фам.* акыл, акыл сәләте; 4. *только мн. кулин.* ми; *на второе подали телячьи мозги* — икенчегә (икенче блюдога) бозау мие бирделәр. ◇ **До мозга костей** *разг.*— чиктән тыш, башыннан аягына кадәр; *до мозга костей глуп* — чиктән тыш аңгыра.

**МО'ЗГЛЫЙ** *обл.*—1. тынчу; *мозглый воздух* — тынчу һава; 2. юеш, яңгырлы; *мозглая погода* — юеш һава, яңгырлы һава.

**МОЗГЛЯ'ВЫЙ** *обл.*— хәлсез, көчсез, зәгыйфь; *мозглявый старик* — хәлсез карт.

**МОЗГЛЯ'К** *м. простореч. презрит.* — яраксыз кеше, сәләтсез кеше, булдыксыз кеше.

**МОЗГОВИ'ТЫЙ** *простореч. фам.* — акыллы, зирәк, башлы.

**МОЗГОВО'Й** —1. *анат.* ми...-ы; *мозговые полушария* — ми ярымшарлары; 2. *перен. книж.* акыл...-ы; баш...-ы; *мозговая работа* — акыл хезмәте.

**МОЗЖЕЧО'К** *м. анат.*— кечкенә ми.

**МОЗЖИ'ТЬ** *безл. разг.*— сыкрау, өзлексез сызлау; *мозжит в колене* — тез буыннарым сызлый.

**МОЗО'ЛИСТЫЙ** — сөялле; *мозолистые руки* — сөялле куллар.

**МОЗО'ЛИТЬ** *несов.:* **мозолить глаза** — йөдәтеп бетерү, теңкәгә тию, ялыктыру.

**МОЗО'ЛЬ** *ж.*— сөял. ◇ **Наступить на любимую мозоль** *разг. шутл. перен.*— авырткан җиренә тию.

**МОЗО'ЛЬНЫЙ** *спец.*— сөял...-ы; *мозольный пластырь* — сөял пластыре.

**МОЙ** *местоим.*—1. минем; *мой сын* — минем улым; 2. *в знач. сказ.* минеке; *это*

*моё* — бу минеке; 3. *в знач. сущ. мн.* нет — минеке; *своё трать, а моего не тронь* — үзеңнекен туздыр, ә минекенә тимә. 4. *мн. в знач. сущ.* — минекеләр, минем семьям. ◇ По-моему — 1) минемчә; минем фикеремчә; 2) мин теләгәнчә.

**МО'ЙКА** *ж.*—1. юу; 2. *тех.* югыч, кер юу машинасы; 3. *(лоханка для мытья чего-н.)* лакан,[1] ләгән.

**МО'ЙНЫЙ** *тех.*— юу...-ы; *мойная машина* — юу машинасы (тукымалар юу өчен).

**МО'ЙЩИК** *м.*, **МО'ЙЩИЦА** *ж. спец.*— юучы (эшче).

**МО'ККА, МО'ККО** *нескл. м.*— мокко (кофеның бер сорты).

**МО'КНУТЬ** *несов.*— юешләнү, чылану.

**МОКРЕ'ДЬ** *ж. мн.* нет, *обл.*— юешлек, пычрак, яңгырлы һава.

**МОКРЕ'НЕК** *просторeч. фам.*— к. мокрёхонек.

**МОКРЁХОНЕК** *просторeч. фам.*— юпьюеш.

**МОКРЕ'Ц** *м. спец.*— пычыргы, юеш тимрәү (атларның аягында була).

**МОКРИ'ЦА** *ж. зоол.*— кыргаяк.

**МОКРОПОГО'ДИЦА** *ж. мн.* нет, *просторeч. шутл.*— юеш һава, яңгырлы көн.

**МОКРО'ТА** *ж. мн.* нет — какырык.

**МОКРОТА'** *ж. мн.* нет, *разг.*— юешлек; юеш әйбер.

**МО'КРЫЙ** — юеш, сулы, дымлы; *мокрая тряпка* — юеш чүпрәк. ◇ **Мокрая курица** — к. курица. **Только мокро останется** *просторeч.*— эзе дә калмас.

**МО'КША** *ж. мн.* нет — мукшы (мордва милләте ике зур группага бүленә, шуларның берсе „мокша", татарча „мукшы" дип атала).

**МОЛ** I *мор.*— мол (портларда судноларны дулкыннан саклау өчен хезмәт итә торган корылма).

**МОЛ** II *ввод. сл. разг.*— дип, дигән бул, диген, имеш; *а не спрашивал он, на что, мол, барину фрак?* (Гоголь) — барингa фрак нигә кирәк, дип сорамадымы соң ул? *он, мол, этого не знал* — ул моны белмәгән, имеш.

**МОЛВА'** *ж. мн.* нет, *устар.*—1. хәбәрләр, сүзләр, имеш-мимешләр; *людская молва* — халык арасында йөри торган сүзләр; 2. фикер; *дурная молва о нём* — аның турында начар фикер йөри.

**МО'ЛВИТЬ** *сов. нар.-поэт.*— әйтү.

**МОЛВЬ** *ж. мн.* нет, *нар.-поэт.* — к. молва.

**МОЛДАВА'НЕ** *мн.*— молдаваннар, молдаван халкы (Молдавия территориясендә һәм Румыниянең төньяк өлкәләрендә яшәүче халык).

**МОЛДАВА'НКА** *ж.*— молдаванка (молдаван хатын-кызы).

**МОЛДАВА'НСКИЙ** — молдаван...-ы; молдаваннар...-ы; *молдаванская одежда*—молдаваннар киеме.

**МОЛДА'ВСКИЙ**—Молдавия...-ы; *Молдавская Советская Социалистическая Республика* — Молдавия Совет Социалистик Республикасы.

**МОЛЕ'КУЛА** *ж. ест.*— молекула (матдәнең барлык химик үзенчәлекләренә ия булган иң кечкенә кисәге).

**МОЛЕКУЛЯ'РНЫЙ** *ест.*—молекуляр; *молекулярный вес* — молекуляр авырлык; *молекулярное давление* — молекуляр басым.

**МОЛЕ'ЛЬНЯ** *ж. рел.*— гыйбадәт йорты, гыйбадәтханә.

**МОЛЕСКИ'Н** *м. спец.*— молескин (калын итеп эшләнгән нык мамык тукыма).

**МОЛЕСКИ'НОВЫЙ** *спец.* — молескин...; молескиннан тегелгән; *молескиновый пиджак* — молескиннан тегелгән пиджак, молескин пиджак.

**МОЛИБДЕ'Н** *м. хим.* — молибден (көмешсыман ак ялтыравыклы каты металл).

**МОЛИ'ТВА** *ж. рел.*— дога, намаз, гыйбадәт.

**МОЛИ'ТВЕННИК** *м. церк.*— догалык.

**МОЛИ'ТВЕННЫЙ** *разг.* — гыйбадәт...-ы; *молитвенный дом* — гыйбадәт йорты.

**МОЛИ'ТЬ** *несов. книж.*— ялыну, үтенү, ялынып сорау, ялвару, инәлү.

**МОЛИ'ТЬСЯ** *несов.*— гыйбадәт кылу, дога уку, намаз уку. ◇ **Молиться** *на кого* — ярату, „үлеп" ярату, исе киту.

**МО'ЛКНУТЬ** *несов. поэт.*— тыну, тынып калу, туктау, басылу.

**МОЛЛЮ'СК** *м. зоол.*— моллюск (күбесенчә кабырчык эчендә яши торган, умырткасыз йомшак тәнле хайван).

**МОЛЛЮ'СКОВЫЙ** *зоол.*— моллюск...-ы; *моллюсковая раковина* — моллюск кабырчыгы.

**МОЛНИЕНО'СНЫЙ** *книж.*—1. яшен...-ы; яшен кебек; яшен тизлегендәге; *с молниеносной быстротой* — яшен тизлеге белән; 2. *устар. поэт. (о туче)* яшенле. ◇ **Кинуть молниеносный взгляд** — ялт итеп карап алу.

**МОЛНИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.*— телеграмма-молния җибәрү, телеграмма-молния белән хәбәр итү, ашыгыч телеграмма җибәрү.

**МО'ЛНИЯ** *ж.* — яшен. ◇ **Телеграмма-молния** — телеграмма-молния, бик ашыгыч телеграмма. **Метать громы и молнии** — авыздан утлар чәчү (ачудан ярсып сөйләү).

**МОЛОДА'ЙКА** *ж. обл.*— к. молодица.

**МОЛОДЁЖНЫЙ** *просторeч.* — яшь...; яшьләр...-ы; *молодёжные кадры* — яшь кадрлар; *молодёжная литература*— яшьләр әдәбияты.

**МОЛОДЁЖЬ** *ж. мн.* нет — яшьләр.

**МОЛО'ДЕНЬКИЙ** *разг.*— бик яшь, яшьяшь, яшь кенә.

**МОЛОДЕ'ТЬ** *несов.*—яшәрү, яшәрә бару.

**МО'ЛОДЕЦ** *м. нар.-поэт.*— батыр, батыр егет, пәһлеван (рус халык эпосындагы геройларга карата кулланыла).

**МОЛОДЕ'Ц** *м.*— 1. егет; булдыклы егет, батыр егет, кыю егет, таза егет; 2. *разг. презрит.* к. молодчик 2.

**МОЛОДЕ'ЦКИЙ** *разг.* и *нар.-поэт.*— егетләр...-ы; батырларча..., егетләрчә...; *молодецкий вид* — егетләр кыяфәте; *молодецкий посвист* — егетләрчә сызгыру.

**МОЛОДЕ'ЧЕСТВО** *ср. мн.* нет — егетлек, батырлык, булдыклылык, кыюлык.

**МОЛОДИ'КА** *ж. мн.* нет, **МОЛОДИ'ЛО** *ср. мн.* нет, *бот.*— куян кәбестәсе, кәрләч, яра үләне.

**МОЛОДИ'ТЬ** *несов. разг.*— яшәртү.

**МОЛОДИ'ТЬСЯ** *несов. разг.*— яшьрәк булып күренергә тырышу.

**МОЛОДИ'ЦА** *ж. обл.*— яшь килен.

**МОЛО'ДКА** *ж.*—1. обл. к. молодица; 2. яшь тавык.

**МОЛОДНЯ'К** *м. мн.* нет — 1. *собир. (приплод)* яшь терлекләр; 2. яшь урман; 3. *разг. собир.* (*молодёжь*) яшьләр, яшь кадрлар.

**МОЛОДОЖЁН** *м. разг.*— 1. яшь кияү; 2. *только мн.* яңа гына өйләнешкән ир белән хатын.

**МОЛОДО'Й** — 1. яшь; *молодое поколение*— яшь буын; 2. яшьлек ...-ы; *молодой задор* — яшьлек дәрте; 3. яңа, яшь; *молодые цыплята* — яшь чебиләр; *молодой месяц* — яңа ай; 4. өлгереп житмәгән; *молодой сыр* — өлгереп җитмәгән сыр; 5. *только мн.* к. молодожён 2.

**МО'ЛОДОСТЬ** *ж. мн.* нет — яшьлек.

**МОЛОДУ'ХА** *ж. обл.*— к. молодица.

**МОЛОДЦЕВА'ТО** *нареч.*— егетләрчә, батырларча.

**МОЛОДЦЕВА'ТОСТЬ** *ж. мн.* нет—егетсыманлык, егетлек.

**МОЛОДЦЕВА'ТЫЙ** — егетсыман, егетләрчә..., батыр, кыю; *молодцеватый вид* — егетләрчә кыяфәт.

**МОЛОДЧА'ГА** *м. мн.* нет, *простореч. фам.*— к. молодчина.

**МОЛО'ДЧИК** *м.* — 1. *простореч. ирон.* алдакчы, хәйләкәр, мошенник; *мы их, молодчиков, на свежую воду выведем* — без ул алдакчыларны фаш итәрбез (йөзләрен ачарбыз); 2. *преимущ. мн. неодобр.* сатлык җаннар, кабахәтләр, ерткычлар (хужаларының кушканына сукырларча буйсынып, теләсә нинди җинаятькә баручылар); *фашистские молодчики* — фашист сатлык җаннар, фашист кабахәтләр. ◇ Подозрительный молодчик — шикле егет.

**МОЛОДЧИ'НА** *м. мн.* нет, *разг. фам.*— к. молодец.

**МО'ЛОДЬ** *ж. спец.*—яшь балык, вак балык, маймыч.

**МОЛОЖА'ВОСТЬ** *ж. мн.* нет — яшь чырайлы булу; яшь чырай.

**МОЛОЖА'ВЫЙ** — яшь чырайлы.

**МОЛО'ЖЕ** — яшьрәк.

**МОЛО'ЗИВО** *ср. мн.* нет — угыз, уыз.

**МОЛО'КИ** *мн. анат.* — балык агы, балык сөте (ата балыкның орлык бизләре һәм шул бизләрдәге сыекча).

**МОЛОКО'** *ср. мн.* нет — сөт. ◇ Молоко на губах не обсохло — к. губа. Кровь с молоком — к. кровь.

**МОЛОКОСО'С** *м. разг. пренебр.*— авызыннан сөте кипмәгән, селәгәй, тәҗрибәсез, яшь кеше.

**МО'ЛОТ** *м. тех.*— зур чүкеч.

**МОЛОТИ'ЛКА** *ж. с.-х.*— молотилка, ашлык сугу машинасы.

**МОЛОТИ'ЛО** *ср. с.-х.* — чабагач тәпәче.

**МОЛОТИ'ЛЬНЫЙ** *с.-х.*—ашлык сугу...-ы; сугу...-ы; *молотильная машина* — (ашлык) сугу машинасы.

**МОЛОТИ'ЛЬЩИК** *м.*—ашлык сугучы.

**МОЛОТИ'ТЬ** *несов.*— ашлык сугу.

**МОЛОТИ'ТЬСЯ** *несов.*— ашлык сугылу.

**МОЛОТОБО'ЕЦ** *м. спец.*— чүкечче, чүкеч белән эшләүче.

**МОЛОТОВИ'ЩЕ** *ср. спец.*— чүкеч сабы.

**МОЛОТО'К** *м.*— чүкеч. ◇ С молотка (продавать) — аукционда сату (берәр милкәтне яки товарны халык алдында артыграк бәя бирүчегә сату).

**МОЛОТО'ЧЕК** *м.* — 1. кечкенә чүкеч; 2. *анат.* чүкеччек (урта колактагы кечкенә сөяк).

**МО'ЛОТ-РЫ'БА** *ж. зоол.* — чүкеч балык (акуланың бер төре).

**МОЛО'ТЬ** *несов.*—1. *(превращать в муку)* тарту; 2. *перен. простореч. фам.* лыгырдау, сөйләү; *молоть вздор* — юкны сөйләү, юкны лыгырдау.

**МОЛОТЬБА'** *ж. мн.* нет, *с.-х.*—1. ашлык сугу; 2. ашлык сугу вакыты.

**МОЛО'ТЬСЯ** *несов. страд.* — (*превращаться в муку*) тартылу.

**МОЛО'Х** *м. мн.* нет — молох (1. *книж.* кешеләрдән корбан таләп итүче усал, аяусыз көч символы; 2. *зоол.* Австралиядә яши торган кәлтә еланның бер төре).

**МОЛОЧА'Й** *м. мн.* нет, *бот.*— сөтлегән, сөтле үлән.

**МОЛО'ЧНАЯ** *в знач. сущ.*— сөт кибете; сөт магазины.

**МОЛО'ЧНИК** *м.*—1. сөт савыты; 2. *разг.* сөт сатучы.

**МОЛО'ЧНИЦА** *ж.*—1. сөтче, сөт сатучы (хатын-кыз); 2. *мед.* гөмбә, сөт авыруы (имчәк балаларында авыз бозылу авыруы).

**МОЛО'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *с.-х.*— сөтлелек, сөт бирүчәнлек.

**МОЛО'ЧНЫЙ** — 1. сөт...-ы; *молочная торговля* — сөт сәүдәсе; *молочные железы* — сөт бизләре; *молочная кислота*—сөт кислотасы; 2. сөтле, сөт бирә торган; *молочная корова* — сөтле сыер; 3. сөтле, сөттән хәзерләнгән; *молочная каша* — сөтле ботка; *молочные продукты* — сөттән хәзерләнгән ашамлыклар. ◇ Молочный брат, молочная сестра *устар.*— сөт кардәшләре (имчәктәш кардәшләр). Молочные зубы *анат.*— сөт тешләре. Молочное стекло *спец.*— тоныкпыяла.

**МО'ЛЧА** *нареч.*— эндәшмичә, берсүзсез, сүз кушмыйча, тын гына, дәшмәстән, дәшмичә, сүз әйтмичә.

**МОЛЧАЛИ'ВОСТЬ** *ж. мн.* нет — аз сүзлелек, сөйләшмәүчәнлек, эндәшмәүчәнлек.

**МОЛЧАЛИ'ВЫЙ** —1. аз сүзле, сөйләшмәүчән; *молчаливый сосед* — аз сүзле күрше; 2. сүзсез; *молчаливое согласие* — сүзсез ризалык.

**МОЛЧА'ЛИНСТВО** *ср. мн.* нет, *книж. публиц.*— начальствога ярарга тырышу, ялагайлык, принципсызлык, карьеризм (Грибоедовның „Акыллылык бәласе" комедиясендәге Молчалин исеменнән).

**МОЛЧА'ЛЬНИК** *м. шутл.*— сөйләми торган кеше, сүзсез кеше, тел яшерүче.

**МОЛЧА'НИЕ** *ср. мн.* нет —1. к. молчать; 2. тынлык; *сохранять молчание* —тынлык саклау.

**МОЛЧА'НКА** *ж.*: **играть в молчанку** — к. играть.

**МОЛЧА'ТЬ** *несов.*—1. эндәшмәү, сөйләшмәү, сүз катмау, сүз кушмау; 2. сөйләмәү, сер итеп саклау; *об этом лучше молчать* — бу турыда сөйләмәү яхшырак; 3. *разг.* хат язмау, хәбәр бирмәү, хәбәр булмау; *молчал два месяца, а теперь чуть не каждый день пишет* — ике ай хәбәре булмады, ә хәзер көн дә диярлек язып тора.

**МОЛЧКО'М** *нареч. просторечю*— эндәшмичә, сүзсез, тын гына, эндәшмичә генә, шыпырт кына.

**МОЛЧО'К** *в знач. сказ. разг.*—1. эндәшмә, шым бул; әйтәсе булма, май кап; *об этом молчок!* — бу турыда май кап (эндәшмә); 2. башка бер сүз дә әйтмәү; *слегка намекнул об этом и молчок* — бу турыда аз гына сиздереп куйды да, башка бер сүз дә әйтмәде.

**МОЛЬ** *ж. мн.* нет — көя.

**МОЛЬБА'** *ж. книж. ритор.*— ялыну, ялвару, инәлү.

**МОЛЬБЕ'РТ** *м. живоп.*— мольберт (художниклар куллана торган махсус станок— агач өчаяк).

**МОМЕ'НТ** *м.*—1. момент, вакыт; *подходящий момент* — унай момент, унай вакыт; 2. шарт; *дисциплина — важный момент в выполнении плана* — дисциплина— планны үтәүдә мөһим шарт.

**МОМЕНТА'ЛЬНО** *нареч.* — 1. кинәт; *смерть наступила моментально* — кинәт үлде, үлем кинәт килде; 2. *перен. разг.* хәзер үк, бик тиз; *моментально вернусь домой* — өйгә хәзер үк кайтырмын.

**МОМЕНТА'ЛЬНЫЙ** — кинәт...; бик тиз ...-ган; *моментальная смерть* — кинәт үлем; *моментальный снимок* — бик тиз төшерелгән рәсем.

**МОНА'ДА** *ж.*—монада (1. *ист.* борынгы математикларда — берлек саны; 2. *филос. ист.* борынгы философларда — яшәешнең нигезендә ятучы принцип; 3. *филос. ист.* идеалистик философиядә — имештер, галәмнең нигезен тәшкил итүче, бүленми торган рухи элементлар; атом төшенчәсен идеалистларча бозып бирү).

**МОНА'РХ** *м. полит. доревол.*— монарх, патша.

**МОНАРХИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *полит.*— монархизм (дәүләт властеның бердәнбер формасы — монархия дигән караштә торучы реакцион-политик юнәлеш).

**МОНАРХИ'СТ** *м.*, **МОНАРХИ'СТКА** *ж. полит.*— монархист, монархистка (монархизм яклы кеше).

**МОНАРХИ'СТСКИЙ** *полит.*—монархистлар...-ы; монархистларча; *монархистский заговор* — монархистлар заговоры; *монархистские взгляды* — монархистларча карашлар.

**МОНАРХИ'ЧЕСКИЙ** *полит.*—1. монархистик, монархия ...-ы; *монархическая власть* — монархистик власть; 2. к. монархистский.

**МОНА'РХИЯ** *ж. книж. полит.*— монархия, монархия дәүләте (бер генә кеше (монарх) тарафыннан идарә ителә торган, феодализм эпохасына характерлы булган деспотик дәүләт идарәсе формасы).

**МОНАСТЫ'РСКИЙ** — монастырь...-ы; монастырьдагы; монастырь карамагындагы; *монастырская жизнь* — монастырь тормышы; *монастырские земли* — монастырь карамагындагы җирләр.

**МОНАСТЫ'РЬ** *м.*— монастырь (1. монахлар яки монашкалар общинасыннан торган чиркәү оешмасы; 2. *собир.* шул община членнары; 3. шул община карамагындагы чиркәү һәм йортлар).

**МОНА'Х** *м.*— 1. монах (чиркәү общинасына член булып кергән һәм яшәү өчен монастырьга күчкән кеше); 2. *перен. разг. шутл.* и *ирон.* суфый кеше.

**МОНА'ХИНЯ** *ж.*— монахиня (к. монах).

**МОНА'ШЕСКИЙ** — 1. монахлар...-ы; *монашеский орден* — монахлар ордены (оешмасы); 2. *перен. разг. шутл.* и *ирон.* суфыйларча...; *монашеским известен поведеньем* (Грибоедов) — үзен суфыйларча тотуы белән танылган.

**МОНА'ШЕСТВО** *ср. мн.* нет, *книж.*— 1. монахлык, монахлар тормышы; 2. *собир, устар.* монахлар.

**МОНА'ШЕСТВОВАТЬ** *несов.*— монах булу, монахларча яшәү.

**МОНА'ШКА** *ж. разг. фам. неодобр.*— к. монахиня.

**МОНГО'ЛКА** *ж.* — монголка, монгол хатын-кызы.

**МОНГОЛОВЕ'Д** *м.*— монголовед (монголоведение белгече).

**МОНГОЛОВЕ'ДЕНИЕ** *ср. мн.* нет— монголоведение (монгол телен, әдәбиятын, культурасын өйрәнә торган фәннәр җыелмасы).

**МОНГО'ЛЫ** *мн.* — монголлар, монгол халкы. (Монголия Халык Республикасында һәм Кытайның Эчке Монголия автономияле өлкәсендә яшәүче халык).

**МОНГО'ЛЬСКИЙ** — монгол...-ы; Монголия...-ы; *монгольский язык* — монгол теле; *Монгольская Народная Республика* — Монголия Халык Республикасы.

**МОНЕ'ТА** *ж.*— акча; *серебряная монета* — көмеш акча. ◇ **Платить той же монетой** *разг.*— бәйрәм ашы кара-каршы. **Принимать за чистую монету** *разг.*— дөрес дип белү, дөрес дип ышану, ышану, чынга алу.

**МОНЕ'ТНЫЙ** —1. *фин.* акча...-ы; *монетная единица* — акча берәмлеге; 2. акча сугу...-ы; *монетный станок* — акча сугу станогы.

**МОНЕ'ТЧИК** *м.*— акча сугучы, акча ясаучы. ◇ **Фальшивый монетчик** *просторечь.*— ялган акча ясаучы.

**МОНИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *филос.*— монизм (дөньяның һәм андагы күренешләрнең нигезендә бер генә башлангыч ята дип раслый торган философик система; идеалистик монизм карашынча, бу башлангыч — рух, материалистик монизм карашынча — материя).

**МОНИ'СТ** *м. филос.*— монист (монизм яклы кеше).

**МОНИСТИ'ЧЕСКИЙ** *филос.*— монистларча...; *монистический взгляд на историю* — тарихка монистларча караш.

**МОНИСТИ'ЧНЫЙ** *филос.* — монистик; монизм белән сугарылган.

**МОНИ'СТО** *ср.*— муенса.

**МОНИТО'Р** *м.*—1. *мор.* монитор (сугыш корабленең бер төре); 2. *горн.* су сиптергеч.

**МОНОГАМИ'ЧЕСКИЙ** *этнол.*— моногамия...-ы; моногамик; *моногамическая система* — моногамия системасы.

**МОНОГА'МИЯ** *ж. мн.* нет, *этнол.*— бер хатын (ир) белән тору, бер хатынлылык, бер ирлелек.

**МОНОГА'МНЫЙ** *этнол.*— к. моногамический.

**МОНОГРА'ММА** *ж.*— монограмма (ике яки берничә хәрефне укмаштырып язу, чигү яки сурәтләү).

**МОНОГРАФИ'ЧЕСКИЙ** *науч.*— монографик; *монографическое исследование* — монографик тикшеренү.

**МОНОГРА'ФИЯ** *ж. науч.*— монография (аерым бер мәсьәләне, теманы тикшерүгә багышланган гыйльми әсәр).

**МОНО'КЛЬ** *м.*— монокль (бер генә күзгә киеп, күзлек урынына файдаланыла торган оптик пыяла).

**МОНОКУЛЬТУ'РА** *ж. с.-х.*— монокультура (бер үк кырда ел саен бер үк төрле культура игү).

**МОНОЛИ'Т** *м. книж.*— монолит (бөтен бер зур таш, шуннан ясалган әйбер).

**МОНОЛИ'ТНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— монолитлык, ныклык, бердәмлек.

**МОНОЛИ'ТНЫЙ** *книж.*— 1. монолит...; бөтен бер таштан эшләнгән; *монолитная колонна* — монолит колонна; 2. *перен.* монолит, бердәм, таркалмаслык нык, көчле; *монолитная коммунистическая партия*— бердәм коммунистлар партиясе; *монолитная личность* — көчле шәхес.

**МОНОЛО'Г** *м. лит. театр.*— монолог (пьесада катнашучының үз-үзенә яки тамашачыларга мөрәҗәгать итеп сөйләве).

**МОНОЛОГИ'ЧЕСКИЙ** *лит. театр.*—монологик; *монологическая речь* — монологик сөйләм.

**МОНОМА'Н** *м. мед.*— мономан, мономания белән авыручы.

**МОНОМА'НИЯ** *ж. мн.* нет, *мед.*— мономания (берәр әйбергә, фикергә һ. б. ларга бирелеп саташу — акылдан язу).

**МОНОМЕТАЛЛИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *экон.*— монометаллизм (кыйммәт үлчәве булып бер генә металл, алтын яки көмеш, кулланыла торган акча системасы).

**МОНОМЕТАЛЛИ'ЧЕСКИЙ** *экон.*— монометаллик; *монометаллическое денежное обращение* — монометаллик акча йөреше.

**МОНОПЛА'Н** *м.*— моноплан (бер генә пар канатлы самолёт).

**МОНОПОЛИЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. книж.*— монополияләштерү, монополиягә алу; *монополизировать внешнюю торговлю* — тышкы сәүдәне монополияләштерү.

**МОНОПОЛИЗИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. книж.*— монополияләштерелү, монополиягә алыну.

**МОНОПОЛИ'СТ** *м. книж.*— монополист, монополияче (1. берәр өлкәдә монополия белән файдаланучы; 2. эре капиталист, монополистик капитал вәкиле).

**МОНОПОЛИСТИ'ЧЕСКИЙ** *экон.*— монополистик; *монополистическое объединение* — монополистик берләшмә; *монополистический капитализм* — монополистик капитализм

**МОНОПОЛИ'СТСКИЙ** *книж.*— монополист...-ы; монополистлык...-ы; *монополистские тенденции* — монополист тенденцияләре; монополистлык тенденцияләре.

**МОНОПО'ЛИЯ** *ж.*— монополия (1. берәр нәрсәне җитештерүнең янсә сатуның бер генә кеше, бер төркем кешеләр яки дәүләт кулында гына булу хокукы; 2. хуҗалыкның берәр өлкәсендә хакимлек итү һәм максималь табыш алу өчен капиталны концентрацияләү нигезендә барлыкка килгән эре капиталистик берләшмә).

**МОНОПО'ЛЬНЫЙ** *книж.*— монополия ...-ы; монополияле; *монопольное право* — монополия хокукы; *монопольная торговля*— монополияле сәүдә.

**МОНОТЕИ'ЗМ** *м. мн.* нет — монотеизм, алла бер дип белү, бер аллага ышану.

**МОНОТО'ННЫЙ** *книж.*—1. бертөрле (тавышлы), үзгәрешсез; 2. эчпошыргыч, күңелсез; *монотонная жизнь* — эчпошыргыч тормыш.

**МОНПАНСЬЕ'** *ср. нескл.*— монпаси (конфетның бер төре).

**МОНТА'Ж** *м.*— монтаж (1. *тех.* машинаның аерым частьларын җыю; 2. берәр нәрсәнең аерым кисәкләрен бер тәртип белән тезеп, бер бөтен хәлгә китерү).

**МОНТАЖЁР, МОНТАЖИ'СТ** *м. спец.*— монтажёр (монтаж эше буенча белгеч, монтаж остасы).

**МОНТА'ЖНИК** *м. спец.*— монтажник, монтёр 1.

**МОНТА'ЖНЫЙ** *спец.*— монтаж...-ы; монтажлау...-ы; төзү...-ы; җыю...-ы; *монтажная мастерская* — монтаж мастерское, җыю мастерское.

**МОНТЁР** *м.*— монтёр (1. *тех.* машиналар коручы, машиналар җыючы, машиналар көйләүче; 2. *разг.* электромонтёр).

**МОНТИ'РОВАТЬ** *несов. спец.*— кору, җыйнау, җыю, төзү, урнаштыру.

**МОНТИ'РОВАТЬСЯ** *несов. спец.*— җый-

налу, корылу, төзелү, җыелу, урнаштырылу.

**МОНУМЕ'НТ** *м. книж. торж.*— һәйкәл, монумент, зур памятник.

**МОНУМЕНТА'ЛЬНЫЙ** *книж.*—1. *архит.* монументаль, зур, мәһабәт; *монументальное здание* — монументаль бина; 2. *перен.* бик зур, тирән эчтәлекле, нигезле; *монументальный труд* — бик зур әсәр; *монументальное исследование* — нигезле, зур тикшеренү.

**МОПС** *м.*— мопс (зур башлы, яньчек борынлы бүлмә эте).

**МОР** *м. разг. устар.*— үләт, эпидемия.

**МОРАЛИЗИ'РОВАТЬ** *несов. книж.*— әхлак өйрәтү, әдәпкә өйрәтү, мораль уку, үгет-нәсихәт сөйләү.

**МОРАЛИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *книж.*— морализм (мораль укуга һәвәслек, моралистлык).

**МОРАЛИ'СТ** *м. книж.*— 1. моралист, әхлак турында язучы, әхлакка өйрәтүче, әдәпкә өйрәтүче, үгет-нәсихәт сөйләүче; 2. *ирон.* үгетләргә яратучы.

**МОРА'ЛЬ** *ж. мн.* нет —1. мораль, әхлак, әдәп; *коммунистическая мораль* — коммунистик мораль (коммунизм төзү максатларына хезмәт итә торган әхлак, мораль); *человек высокой морали* — бик әхлаклы кеше; 2. мораль, гыйбрәтле нәтиҗә, гыйбрәт; *мораль басни* — мәсәлдән гыйбрәт, мәсәлнең морале; 3. *разг.* үгет-нәсихәт, мораль; *читать мораль* — үгет-нәсихәт бирү.

**МОРА'ЛЬНО-ПОЛИТИ'ЧЕСКИЙ**—моральполитик; *морально - политическое единство советского народа* — совет халкының мораль-политик бердәмлеге.

**МОРА'ЛЬНЫЙ** *книж.*— 1. әхлак...-ы; *моральные устои* — әхлак кагыйдәләре; 2. әхлаклы, әдәпле; *высокоморальный человек*— бик әхлаклы кеше; 3. мораль...; *оказать моральную помощь* — мораль ярдәм күрсәтү.

**МОРГ** I *м.*— морг (мәетләр бүлмәсе, җирләгәнгә кадәр мәетләрне куя торган бүлмә яки аерым бина).

**МОРГ** II *м.*— морг (0,5 га чамасында җир үлчәве).

**МОРГАНИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *биол.*—морганизм (биология фәнендә реакцион идеалистик агым).

**МОРГА'ТЬ** *несов.*— күз кыскалау, күз йомгалау, күзләрне еш-еш кына ачыпйомып тору.

**МОРГНУ'ТЬ** *однокр.*— күз кысып кую. ◇ **Глазом не моргнуть** *простореч.* — тартынып тормау, тәвәккәллек итү.

**МОРГУ'Н** *м.*, **МОРГУ'НЬЯ** *ж. простореч.*— күз кысучы, күзләрен еш-еш ачыпйомып торучы.

**МО'РДА** I *ж.*—1. (*у животных*) танау, борын (хайваннарда башның авыз, борын, няктән торган түбән өлеше); 2. *вульг.* бит, йөз; ямьсез бит.

**МО'РДА** II *ж.*— морда, сөрәкә (балык тоту коралы).

**МОРДА'СТЫЙ** — 1. *разг.* зур танаулы (хайван); 2. *простореч.* зур битле, зур йөзле (кеше).

**МОРДА'ШКА** *м.* и *ж. фам.*— чибәр йөз.

**МОРДВА'** *ж. мн.* нет — мордва, мордва халкы (Мордва АССРның төп халкы).

**МОРДВИ'Н** *м.*— мордвин (мордва милләтеннән булган кеше).

**МОРДО'ВСКИЙ** — мордва...-ы; *мордовский народ* — мордва халкы.

**МО'РЕ** *ср.* — 1. диңгез; *Балтийское море* — Балтик диңгезе; 2. *перен.* диңгез, диңгездәй күп, бик күп, чиксез күп; *море слёз* — күз яше диңгезе (бик күп түгелгән яшь); *море хлебов* — диңгездәй (җәелеп яткан) игеннәр, игеннәр диңгезе. ◇ **Море по колено** — диңгез тубыктан. **Житейское море** — тормыш диңгезе.

**МОРЕ'НА** *ж. геол.*— морена (бозлыклар белән бергә шуышып төшкән тау токымнарының, зур-зур таш кисәкләренең өемнәре).

**МОРЕПЛА'ВАНИЕ** *ср. мн.* нет —диңгездә йөрү, диңгез сәяхәте; диңгездә йөзү сәнгате.

**МОРЕПЛА'ВАТЕЛЬ** *м.*— диңгез сәяхәтчесе.

**МОРЕПЛА'ВАТЕЛЬНЫЙ** — диңгездә йөрү ...-ы; *мореплавательные качества судна*— судноның диңгездә йөрү сыйфатлары.

**МОРЕХО'ДНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *спец.*— диңгездә йөрү яки йөрерлек сәләт (яраклык); *гидросамолёт обнаружил хорошую мореходность* — гидросамолёт диңгездә йөрү сәләте яхшы булуын күрсәтте.

**МОРЕХО'ДНЫЙ** *устар.*— к. мореплавательный.

**МОРЕХО'ДСТВО** *ср. мн.* нет. *устар.*— к. мореплавание.

**МОРЖ** *м. зоол.*— морж (диңгездә яши торган имезүче хайван).

**МОРЖИ'ХА** *ж. зоол.*— ана морж.

**МОРИ'ЛКА** *ж. спец.*— морилка (мебель, карандаш кебек әйберләр ясалачак агачка сеңдерелә торган зәһәр сыекча).

**МОРИ'ТЬ** I *несов.*— 1. кыру, үтерү, үтереп бетерү; *морить крыс* — күселәрне кыру; 2. *перен.* җәфалау, интектерү; *морить голодом* — ачыктырып җәфалау; 3. *разг. фам.* көлдереп ялыктыру, көлдереп йөдәтү, көлдереп хәлдән тайдыру; *своим рассказом морил нас до самой ночи* — кызыклы вакыйгалар сөйләп безне төнгә кадәр көлдереп йөдәтә иде, көлдереп хәлдән тайдыра иде; 4. *обл.* сүндерү (күмерне); 5. талдыру; *морить хрен* — керән талдыру.

**МОРИ'ТЬ** II *несов. спец.*— морилка сөртү, морилка белән буяу; *морить дуб* — имәнгә морилка сөртү (мебель ясаганда).

**МОРКО'ВКА** *ж. разг.*— кишер, бер дānә кишер.

**МОРКО'ВНЫЙ** — кишер...-ы; *морковный сок* — кишер согы.

**МОРКО'ВЬ** *ж. мн.* нет — кишер.

**МОРКО'ТНО** *безл. в знач. сказ. обл.*— күңелсез, ямансу.

**МОРОВО'Й**: **моровое поветрие** — үләт; **моровая язва** — чума.

**МОРО'ЖЕНОЕ** *ср.*— морожный.

**МОРО'ЖЕНЫЙ** — 1. туңдырылган; *мороженая рыба* — туңдырылган балык; 2. өшегән, өшеп бозылган; *мороженый картофель* — өшегән бәрәңге.

**МОРО'З** *м.*— салкын, суык. ◇ **Мороз по коже дерёт** — салкын тәнне чеметтереп ала.

**МОРО'ЗИТЬ** *несов.*—1. катыру, туңдыру, өшетү; *морозить тараканов* — таракан-нарны катыру; *морозить яблоки* — алмаларны өшетү; 2. *безл.* суыту, салкынайту; *сегодня морозит* — бүген салкынайтып тора; бүген көн суык.

**МОРО'ЗИТЬСЯ** *несов. страд. разг.*— өшетелү, катырылу, туңдырылу.

**МОРО'ЗНО** *в знач. сказ.*— салкын, бик салкын, суык.

**МОРО'ЗНЫЙ** —1. салкын, суык; *морозное утро* — салкын иртә; 2. кар...-ы; *морозная пыль* — кар тузаны.

**МОРОЗОСТО'ЙКИЙ, МОРОЗОУСТО'ЙЧИВЫЙ** *спец.*— салкынга чыдам; *морозостойкие сорта малины* — кура җиләгенең салкынга чыдам сортлары.

**МОРО'КА** *ж. обл.* —1. аңлаешсызлык, буталчыклык, тәртипсезлек; 2. акылдан язу.

**МОРОКОВА'ТЬ** *несов.*— к. мараковать.

**МОРОСИ'ТЬ** *несов.*— пыскаклау, пыскаклап яву, сибәләү, сибәләп тору.

**МОРО'ЧИТЬ** *несов. разг.*— баш катыру, баш әйләндерү, ялгыштыру; *меня не морочьте* — башымны әйләндермәгез.

**МОРО'ШКА** *ж. мн.* нет — морошка (мүк җиләгенең бер төре).

**МОРС** *м. мн.* нет — морс (җимеш суыннан хәзерләнгән салкын эчемлек).

**МОРСКО'Й** — диңгез...-ы; диңгездә ...; *морская вода* — диңгез суы; *морское купанье* — диңгездә су керү, диңгездә су коену.

**МОРТИ'РА** *ж. воен.*— мортира (кыска көпшәле орудие).

**МОРТИ'РНЫЙ** *воен.*— мортира...-ы; *мортирная батарея* — мортира батареясы.

**МОРФЕ'МА** *ж. лингв.*— морфема (сүзнең яңадан мәгънәле кисәкләргә бүленми торган өлеше: тамыр, суффикс, кушымча).

**МО'РФИЙ** *м. мн.* нет, *апт.*— морфий (авыртуны баса торган наркотик матдә, дару).

**МОРФИНИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *мед.*— морфинизм (морфийны исерткеч итеп куллануга бирелү).

**МОРФИНИ'СТ** *м.*, **МОРФИНИ'СТКА** *ж. мед.*— морфинист, морфинизм белән җәфаланучы.

**МОРФО'ЛОГ** *м. науч.* — морфолог, морфология белгече.

**МОРФОЛОГИ'ЧЕСКИЙ** *науч.*— морфологик; *морфологические наблюдения* — морфологик күзәтүләр.

**МОРФОЛО'ГИЯ** *ж. мн.* нет — морфология (1. үсемлек һәм хайван организмнарының төзелеше турындагы фән; 2. *лингв.* грамматиканың сүз формаларын өйрәнә торган бүлеге һәм нинди дә булса телнең барлык сүз формалары).

**МОРЩИ'НА** *ж.* — җыерчык.

**МОРЩИ'НИСТЫЙ** — җыерчыклы; *морщинистое лицо* — җыерчыклы бит.

**МОРЩИ'НИТЬ** *несов.*— җыерчыкландыру; *морщинят мысли лоб её* (Маяковский) — уйлар аның маңгаен җыерчыкландыралар.

**МОРЩИ'НКА** *ж.*— вак җыерчык; бер җыерчык.

**МО'РЩИТЬ** *несов.*—1. җыеру; *морщить лоб* — маңгай җыеру; 2. *перен.* шадраландыру; *ветерок воду морщит* — җил суны шадраландыра. ◇ **Морщить губы** — ирен турсайту. **Морщить лицо** — чырай сыту.

**МОРЩИ'ТЬ** *несов. разг.* — җыерылу, җыерылып тору, тигез ятмау; *платье морщит* — күлмәк җыерылып тора.

**МО'РЩИТЬСЯ** *несов.*—1. маңгай җыеру; 2. чырай сыту, ирен турсайту; 3. *разг.* (*о вещах)* җыерчыклану.

**МОРЯ'К** *м.*—1. моряк (флотта хезмәт итүче); 2. *разг.* диңгез сәяхәтчесе; 3. *разг.* диңгездән искән җил.

**МОРЯ'НКА** *ж. зоол.*— поляр казы, морянка.

**МОСКАТЕ'ЛЬ** *ж. мн.* нет, *собир.*— москатель (сату өчен билгеләнгән буяу, җилем, буяу мае кебек әйберләр).

**МОСКАТЕ'ЛЬНЫЙ** — москатель...-ы; *москательные товары* — москатель товарлары.

**МОСКАТЕ'ЛЬЩИК** *м.*— москательче, москатель товарлары сатучы.

**МОСКИ'Т** *м. зоол.*— москит (бик каты итеп тешли торган көньяк чебене).

**МОСЛА'К** *м. обл.*— к. мосол.

**МОСО'Л** *м. обл.*— зур сөяк (бот сөяге).

**МОСТ** *м.*— күпер.

**МО'СТИК I** *м.:* **капитанский мостик** — капитан күперчеге (суднода капитан өчен ясалган вышка).

**МО'СТИК II** *м.*— кечкенә күпер, басма.

**МОСТИ'ЛЬЩИК** *м.*— юлга таш җәюче; күпер салучы.

**МОСТИ'ТЬ** *несов.*—җәю, түшәү; *мостить улицы асфальтом* — урамнарга асфальт җәю. ◇ **Мостить мост** — күпер салу.

**МОСТИ'ТЬСЯ** *несов. страд.*— җәелү, түшәлү (асфальт, күпер).

**МОСТКИ'** *мн.*— басма.

**МОСТОВА'Я** *ж.*— мостовой (таш түшәлгән юл, урам).

**МОСТОВИ'К** *м. спец.*— күпер салучы, күпер эшләүче, күпер төзүче (белгеч).

**МОСТОВО'Й** *тех.*— күпер...-ы; *мостовые быки* — күпер баганалары.

**МОСТОВЬЁ** *ср. мн.* нет — эре терлек тиреләре (иләнгән, ләкин эшкәртелмәгән).

**МОСТО'К** *м.*— к. мостик II.

**МОСЬЕ'** *м. нескл. устар.*—1. мосьё, әфәнде (французларга мөрәҗәгать итү сүзе); 2. гувернёр-француз.

**МО'СЬКА** *ж. разг.*— кечкенә эт, моська, мүчкәй.

**МОТ** *м.*, **МОТО'ВКА** *ж.*— акча туздыручы, мут кеше.

**МОТА'ЛКА** *ж. обл. тех.*— эвернә (уралган җепне сүтү өчен кулланыла торган җайланма).

**МОТА'ЛЬНЫЙ** *тех.*— урау...-ы; чорнау ...-ы; чорнау өчен хезмәт итә торган; *мотальный цех*—урау цехы; *мотальная машина* — чорнау машинасы (чорнау өчен хезмәт итә торган машина).

**МОТА'ТЬ** I *несов.*—1. урау, чорнау; *мотать нитки* — җеп чорнау; 2. чайкау, селкү, кагу; *мотать головой* — баш чайкау; 3. *перен. простореч.* интектерү, аптырату; *очень устаю: мотают меня целый день* — бик арыйм: көн буе аптыраталар мине. ◇ **Мотать на ус** — истә тоту, колакка алу, мыекка чорнау, хәтердә калдыру.

**МОТА'ТЬ** II *несов. разг.*— туздыру, түгү, әрәм-шәрәм итү; *мотать деньги* — акча туздыру.

**МОТА'ТЬСЯ** I *несов. разг.*—1. *страд.* уралу, чолгану, чорналу; 2. селкенү, чайкалу, тирбәлү; *верёвка мотается от ветра* — бау җилдән селкенә.

**МОТА'ТЬСЯ** II *несов. разг.*— 1. йөрү, әрле-бирле йөрү, алкы-салкы йөрү, аяк астында уралып йөрү, мәгънәсезгә вакыт үткәрү; *мотаться с утра до ночи по делам* — иртәдән алып кичкә кадәр эш артыннан әрле-бирле йөрү; *мотаться без дела по целым дням* — көннәр буе эшсез йөрү; 2. (авырлык белән) гизеп йөрү, (авырлык белән) гизү, каңгырып йөрү; *мотаться по свету* — авырлык белән дөнья гизеп йөрү, каңгырып йөрү.

**МОТА'ТЬСЯ** III *несов. разг. страд.*— туздырылу, түгелү, әрәм-шәрәм ителү (акча).

**МОТИ'В** I *м.*— 1. *книжн.* сәбәп, сылтау; *по мотивам личного характера* — шәхси характердагы сәбәпләр белән; 2. *книжн.* дәлил; *привести мотивы в пользу своего предложения* — үз тәкъдимең файдасына дәлилләр китерү.

**МОТИ'В** II *м.*—1. *спец.* мотив (нигез момент, төп тема, сюжет); *осенние мотивы в картинах Левитана* — Левитан картиналарында көз мотивлары; 2. *муз.* көй; *весёлый мотив* — күңелле көй.

**МОТИВИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.*— дәлилләү, нигезләү, дәлилләр китерү; *мотивировать своё предложение* — үз тәкъдимеңне дәлилләү.

**МОТИВИРО'ВКА** *ж. книжн.*—1. к. мотивировать; 2. барлык дәлилләр (җыелмасы); *убедительная мотивировка* — ышандырырлык дәлилләр.

**МОТИВИРО'ВОЧНЫЙ** — дәлилләү ...-ы; дәлилләр китергән; *мотивировочная часть резолюции* — резолюциянең дәлилләр китерелгән өлеше.

**МО'ТКА** *ж. мн.* нет, *простореч. фам.*— к. мотня.

**МОТНУ'ТЬ** *однокр.*— чайкап кую, селкеп кую.

**МОТНЯ'** I *ж. обл.*—1. чалбар төбе; 2. *рыболов.* ятьмә койрыгы.

**МОТНЯ'** II *ж. мн.* нет, *простореч.*— әрле-бирле йөрү, ыгы-зыгы килү.

**МОТОВИ'ЛО** *ср. тех.*— эвернә, канат (җеп урау өчен булган җайланма).

**МОТОВИ'ЛЬЩИК** *м.*— җеп урачы эшче.

**МОТОВО'З** *м. тех.*— мотовоз (аз җегәрле эчке янулы двигатель ярдәмендә хәрәкәт итә торган локомотив).

**МОТОВСТВО'** *ср. мн.* нет, *разг.*— мутлык, әрәм-шәрәм итү, туздыру.

**МОТОГО'НКИ** — мотоциклетта узышу.

**МОТО'К** *м.* — басма, бәйләм; *моток ниток* — җеп бәйләме.

**МОТОКА'ДА** *ж. спорт.*— мотокада, мотоциклистлар отряды.

**МОТОКУЛЬТУ'РА** *ж. мн.* нет, *с.-х.*—мотокультура (туфрак эшкәртү өчен механик двигательләр куллану).

**МОТОМЕХАНИЗИ'РОВАННЫЙ** — мотомеханизацияләштерелгән; *мотомеханизированная войсковая часть* — мотомеханизацияләштерелгән гаскәри бүлек.

**МОТОПЕХО'ТА** *ж. мн.* нет—мотопехота, моторлаштырылган пехота (автомобильләр, мотоцикллар һ. б. белән тәэмин ителгән пехота).

**МОТОПИЛА'** *ж.*— моторлы пычкы (мотор ярдәмендә кисә торган пычкы).

**МОТО'Р** *м.*— мотор, двигатель.

**МОТОРИЗА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *спец.*— моторизация, моторлаштыру (моторлы машиналарны күбәйтү).

**МОТОРИЗОВА'ТЬ** *сов.* и *несов. спец.*— моторлаштыру, автотранспортны киң рәвештә җәелдерү, моторлы машиналарны күбәйтү.

**МОТОРИ'СТ** *м.*, **МОТОРИ'СТКА** *ж. спец.*— моторист (моторлы машинада эшләүче).

**МОТО'РКА** *ж. разг.*— моторлы көймә.

**МОТО'РНЫЙ** I *тех.*— моторлы; *моторная лодка* — моторлы көймә.

**МОТО'РНЫЙ** II *тех. физиол.*— хәрәкәт ...-ы; *моторные центры* — хәрәкәт үзәкләре; *моторные рефлексы* — хәрәкәт рефлекслары.

**МОТОЦИ'КЛ, МОТОЦИКЛЕ'Т** *м. разг.*— мотоцикл, мотоциклет.

**МОТОЦИКЛИ'СТ** *м.*— мотоциклист, мотоциклда йөрүче.

**МОТО'ЧНЫЙ** *спец.*— басмалы; бәйләмле; *моточная пряжа* — бәйләмле җеп.

**МО'ТТО** *ср. нескл.*— кыска эпиграф (китап башына яки китапның бүлеге башына языла).

**МОТЫ'ГА** *ж. с.-х.*— китмән, мотыга.

**МОТЫ'ЖИТЬ** *несов. с.-х.*— китмәнләү, китмән белән эшкәртү.

**МОТЫ'ЖНЫЙ** — мотыга белән...; китмән белән...; *мотыжное земледелие* —мотыга белән җир эшкәртү.

**МОТЫЛЁК** *м.*— вак күбәләк.

**МОТЫ'ЛЬ** *м.*—1. озынборын личинкасы; 2. *тех. устар.* к. кривошип.

**МОХ** *м.*— мүк.

**МОХНА'ТЫЙ** — йонлач, йөнтәс, йонлы.

**МОХНОНО'ГИЙ** *разг.* — йонлач аяклы,

төкле аяклы; *мохноногая птица* — йонлач аяклы кош, төкле аяклы кош.

**МОХООБРА'ЗНЫЙ** *книж. бот.* — мүккә охшашлы, мүккә охшаган, мүксыман.

**МОЦИО'Н** *м. разг. мед.* — моцион, прогулка ясау, йөреп кайту (саф һавада йөрү).

**МОЧА'** *ж. мн.* нет — сидек.

**МОЧА'ЛА** *ж.* — к. мочало.

**МОЧА'ЛИСТЫЙ** *разг.* — мунчала кебек, мунчалаланган, мунчаладай.

**МОЧА'ЛИТЬ** *несов. спец.* — мунчалага әйләндерү, мунчалаландыру, ваклау, теткәләү.

**МОЧА'ЛКА** *ж.* — мунчала, югыч (әйбер юу яки юыну өчен).

**МОЧА'ЛО** *ср.* — мунчала (юкәдән алынган).

**МОЧА'ЛЬНЫЙ** — мунчала...; мунчаладан ясалган; *мочальный матрац* — мунчала матрац.

**МОЧЕВИ'НА** *ж. мн.* нет — 1. сидекчә (сидектә була торган азотлы матдә); 2. мочевина (азотлы ашлама).

**МОЧЕВО'Й** — сидек...-ы; *мочевой канал* — сидек юлы.

**МОЧЕГО'ННЫЙ** *мед.* — сидерткеч, сидертә торган; *мочегонные средства* — сидерткеч средстволар.

**МОЧЕИЗНУРЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *мед.* — күп сию, сидек агу (авыру).

**МОЧЕИСПУСКА'НИЕ** *ср. мн.* нет, *физиол.* — сию.

**МОЧЕИСПУСКА'ТЕЛЬНЫЙ** *анат.* — сидек...-ы; сидек чыга торган; *мочеиспускательный канал* — сидек каналы.

**МОЧЕИСТОЩЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *мед. устар.* — к. мочеизнурение.

**МОЧЁНЫЙ** — чылатылган, җебетелгән; *мочёные яблоки* — чылатылган алмалар; *мочёная глина* — җебетелгән балчык.

**МО'ЧЕНЬКА** *ж. мн.* нет, *простореч. фам.:* моченьки нет, моченьки не стало — көчем юк, хәлем юк, җегәрем юк, җегәрем бетте, чыдар хәлем калмады, түзәр хәлем калмады.

**МОЧЕОТДЕЛЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *физиол.* — сидек бүленеп (аерылып) чыгу (бөер аша).

**МОЧЕОТДЕЛИ'ТЕЛЬНЫЙ** *физиол.* — сидек бүлеп (аерып) чыгара торган.

**МОЧЕТО'ЧНИК** *м. анат.* — сидек юлы.

**МОЧИ'ЛО** *ср. с.-х.* — (житен) чылату урыны, (житен) чылату савыты.

**МОЧИ'ЛЬНЫЙ** *спец.* — чылату...-ы; *мочильный чан* — чылату чаны.

**МОЧИ'ТЬ** *несов.* — чылату, юешләтү, җебетү.

**МОЧИ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. *страд.* чылатылу; *лён мочится* — житен чылатыла; 2. *разг.* сию; 3. *простореч.* чылану, җебү, юешләнү.

**МО'ЧКА I** *ж. мн.* нет, *спец.* — чылату, җебетү, юешләтү.

**МО'ЧКА II** *ж.* — 1. *анат.* колак йомшагы, колак яфрагы; 2. *бот.* чук, тамыр чугы; 3. ияр эләмәге (ат сбруенда).

**МОЧКОВА'ТЫЙ** *бот.:* мочковатая корневая система — чук тамырлар системасы, чуклы тамырлар системасы.

**МОЧЬ I** *несов.* — ...-а алу; *он может поднять 100 кг* — ул 100 *кг* күтәрә ала. ◇ Может или может быть — бәлки, ихтимал. Не может быть! — булмас! булуы мөмкин түгел! мөмкин түгел! Как живёте-можете? — ничек яшисез? Не могу знать — белмим.

**МОЧЬ II** *ж. мн.* нет, *просторeч.* — көч, куәт, җегәр; *бежать во всю мочь* — бөтен көчкә йөгерү. ◇ Мочи нет (как) *разг.* — көчем юк, хәлем юк, җегәрем юк, җегәрем бетте, түзәр хәл юк, чыдарлык түгел, түзәргә мөмкин түгел.

**МОШЕ'ННИК** *м.*, **МОШЕ'ННИЦА** *ж.* — мошенник, алдакчы, хыянәтче; жулик, карак.

**МОШЕ'ННИЧАТЬ** *несов. разг.* — алдау, алдашу, хыянәт итү, жуликлык итү.

**МОШЕ'ННИЧЕСКИЙ** — мошенниклар...-ы; мошенникларга хас...; хәйләле; *мошеннические проделки* — мошенникларга хас эшләр; хәйләле, бозык эшләр.

**МОШЕ'ННИЧЕСТВО** *ср.* — алдау, хыянәт; *крупное мошенничество* — зур хыянәт, зур алдау.

**МО'ШКА** *ж.* — вак чебен, черки.

**МОШКАРА'** *ж. мн.* нет, *собир.* — вак чебеннәр, черкиләр.

**МОШНА'** *ж.* — акча янчыгы.

**МОШНИ'ЦА** *ж. книж. устар.* — к. мошна.

**МОШО'НКА** *ж.* — 1. *просторeч. устар.* к. мошна; 2. *анат.* йомырка капчыгы.

**МОШО'НОЧНЫЙ** *анат.* — йомырка капчыгындагы...; йомырка капчыгы...-ы.

**МОЩЁНЫЙ** — түшәлгән; таш түшәлгән; таш җәелгән; *мощёная улица* — таш түшәлгән урам; таш җәелгән урам.

**МО'ЩНОСТЬ** *ж. книж.* — 1. *только ед.* көч, куәт, көчлелек, куәтлелек; 2. *геол.* калынлык, күплек (казылма минерал катлауларының калынлыгы); 3. *тех.* җегәрлек; *двигатель мощностью в сто лошадиных сил* — йөз ат көче җегәрлегендәге двигатель.

**МО'ЩНЫЙ** — 1. көчле, кискен, куәтле; *мощный подъём народного хозяйства* — халык хуҗалыгының кискен күтәрелүе; 2. *тех.* җегәрле, зур җегәрле; *мощный двигатель* — зур җегәрле двигатель; 3. зур, калын; *мощная фигура* — зур гәүдә; *мощный пласт* — калын катлау.

**МОЩЬ** *ж. мн.* нет — көч, куәт, кодрәт.

**МРАЗЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — 1. җирәнгеч, кабахәт, кабахәтлек; 2. җирәнгеч кеше, кабахәт кеше, адәм актыгы.

**МРАК** *м. мн.* нет, *книж.* — 1. караңгылык; *во мраке ночи* — төн караңгылыгында; 2. *перен.* караңгылык, ямансу; *мрак на душе* — күңелдә караңгылык. ◇ Мрак невежества — наданлык, караңгылык. Мрак неизвестности — билгесезлек.

**МРАКОБЕ'С** *м. публиц.* — мракобес, реакционер (прогрессның, фәннең, культураның дошманы).

**МРАКОБЕ'СИЕ** *ср. мн.* нет, *публиц.* — мракобеслык, һәр прогресска каршы килү.

**МРА'МОР** *м. мн.* нет — мрамор, мәрмәр (таш).

**МРАМОРИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. спец.*— мәрмәргә охшатып эшләү, мәрмәргә охшатып бизү.

**МРАМОРИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. спец. страд.*—мәрмәргә охшатып буялу, мәрмәргә охшатып эшләнү.

**МРАМОРИ'СТ** *м. спец.*— мәрмәрче (мәрмәргә охшатып эшләү белгече, эшче).

**МРА'МОРНЫЙ** — 1. мәрмәр...; *мраморная плита* — мәрмәр плита; 2. *перен.* мәрмәрдәй (ак һәм шома); мәрмәр төсле (ак һәм шома); *мраморные плечи* — мәрмәрдәй (ак һәм шома) җилкәләр.

**МРА'МОРЩИК** *м. спец.*— мәрмәрне эшкәртүче, мәрмәр әйберләр ясаучы.

**МРАЧИ'ТЬ** *несов. поэт. устар.*— к. омрачать.

**МРАЧНЕ'ТЬ** *несов.*— караңгылану; *мрачнеть лицом* — йөзе караңгылану, чытыклану.

**МРА'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— караңгылык; күңелсезлек.

**МРА'ЧНЫЙ** — 1. караңгы; *мрачная ночь* — караңгы төн; 2. *перен.* күңелсез, ямансу; *мрачные мысли* — күңелсез уйлар, ямансу уйлар; *мрачная погода* — күңелсез һава; 3. *разг. фам.* чиркәнеч, сөйкемсез; *мрачный тип* — чиркәнеч тип.

**МРЕ'ЖА** *ж. книж. устар. поэт.*— ятьмә.

**МСТИ'ТЕЛЬ** *м. книж.*— үч алучы.

**МСТИ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— үч алучанлык, үч алучан булу; *мстительность характера* — характерның үч алучан булуы.

**МСТИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.*— үч алучан; үч кайтаручан; *мстительный характер* — үч алучан характер.

**МСТИТЬ** *несов.*— үч алу; *мстить врагу* — дошманнан үч алу.

**МТС** (машинно-тракторная станция) *ж.*— МТС (машина-трактор станциясе).

**МУА'Р** *м. мн.* нет — муар (ефәк тукыманың бер төре).

**МУАРИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. спец.*— муарга охшатып буяу (кәгазьне).

**МУА'РОВЫЙ** — 1. муар...; *муаровое платье* — муар күлмәк; 2. муарга охшаган; муар төсле; *муаровая бумага* — муарга охшаган кәгазь.

**МУДРЁНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *разг.*— гаҗәп нәрсә; серлелек, кыенлык, катлаулылык, аңлаешсызлык; *тут никакой мудрёности нет, всё просто* — монда бернинди дә кыенлык юк, бар да гади.

**МУДРЁНЫЙ** *разг.*—1. аңлаешсыз, гаҗәп; *мудрёная штука* — гаҗәп әйбер; 2. кыен, читен, катлаулы, аңлавы авыр; *мудрёная задача* — катлаулы мәсьәлә; 3. *в знач. сказ.* авыр, бик авыр, җиңел түгел, мөмкин түгел, шикле; *эту задачу решить мудрено* — бу мәсьәләне чишү бик авыр. ◇ **Утро вечера мудренее** *пословица* — иртә кичтән хәерлерәк. **Не мудрено, что...** — гаҗәп түгел, табигый; *не мудрено, что он обиделся* — аның үпкәләве гаҗәп түгел.

**МУДРЕ'Ц** *м.*— фикер иясе, зур белем иясе; зур акыл иясе, тирән акыллы кеше, хәким.

**МУДРИ'ТЬ** *несов. ирон.*— акыл сату, фәлсәфә сату, хикмәт чыгару.

**МУДРОВА'ТЬ** *несов. простореч.*— к. мудрить.

**МУ'ДРОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. зур акыллылык, акыллы булу; 2. катлаулылык, хикмәтлелек. ◇ **Зуб мудрости** — акыл теше.

**МУ'ДРСТВОВАТЬ** *разг.*— акыл сату, фәлсәфә сату, хикмәт кору; *не мудрствуя лукаво* — хәйләләп фәлсәфә сатмыйча гына, акыл сатмыйча гына.

**МУ'ДРЫЙ** — зур акыллы, тәҗрибәле, зур белемле, зирәк; *мудрая политика* — зирәк политика; *мудрый совет* — акыллы киңәш.

**МУЖ** *м.* — 1. ир; *мой муж* — минем ирем; 2. *устар.* ир кеше; 3. *книж. устар.* эшлекле; *государственный муж* — дәүләт эшлеклесе; *учёный муж* — фән эшлеклесе.

**МУЖА'ТЬ** *несов. устар.*— үсеп җитү, буйга җитү; балигъ булу, олыгаю, үсеп ныгу.

**МУЖА'ТЬСЯ** *несов.*— нык булу, ирләрчә булу, нык тору, батыр булу, батыраю; *мужайтесь, други* — нык торыгыз, дуслар.

**МУЖЕПОДО'БНЫЙ** — ирләр төсле, ирләргә охшаган, ир чырайлы (хатын-кыз турында).

**МУ'ЖЕСТВЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— батырлык, тәвәккәллек, гайрәтлелек, ныклык, йөрәклелек.

**МУ'ЖЕСТВЕННЫЙ** *книж.*—1. нык, булдыклы, батыр, тәвәккәл, йөрәкле; *мужественная женщина* — (булдыклы) батыр хатын; 2. гайрәтле, көчле; *мужественная наружность* — гайрәтле кыяфәт.

**МУ'ЖЕСТВО** *ср. мн.* нет — батырлык, йөрәклелек, гайрәтлелек, тәвәккәллек.

**МУ'ЖЕСТВОВАТЬ** *несов. книж. устар.*— көрәшү.

**МУЖИ'К** *м.*—1. *доревол.* крестьян, авыл кешесе, мужик; 2. *простореч.* ир кеше; *дельный мужик* — эшлекле кеше (ир кеше турында); 3. *разг. пренебр. устар. (грубый человек)* укымаган кеше, тупас кеше.

**МУЖИ'ЦКИЙ** — крестьян...-ы; крестьяннар...-ы; *в моих жилах течёт мужицкая кровь* (Тургенев) — минем тамырларымда крестьян каны ага.

**МУЖИЧИ'НА** *м. мн.* нет, *простореч.*— зур таза гәүдәле (ир) кеше.

**МУЖЛА'Н** *м. разг. бран.*— тупас (ир) кеше, тәрбиясез (ир) кеше.

**МУ'ЖНИН** (а, о) *разг.* — ир ...-ы; иренең ...ы; *мужнина родня* — иренең туганнары, ир ягыннан булган туганнар.

**МУЖСКО'Й**—1. ир...-ы; ирләр...-ы; *мужской пол* — ирләр җенесе; *мужской костюм* — ирләр костюмы; 2. ирләргә хас; ирләрчә; *мужская ловкость* — ирләрчә осталык; 3. ир балалар ...-ы; *мужская школа* — ир балалар мәктәбе. ◇ **Мужской род** *грам.*— мужской род.

**МУЖЧИ'НА** *м.*— ир кеше.

**МУ'ЗА** *ж.*—1. *миф.* муза (борынгы грек-

ларда фән һәм сәнгать алласы; хатын алла); 2. *перен.* илһам, шигърият чыганагы; 3. шагыйрьнең иҗаты һәм аның үзенчәлекле яклары.

**МУЗЕЕВЕ'Д** *м.*— музей белгече, музейчы (музей эшләрен алып баручы белгеч).

**МУЗЕЕВЕ'ДЕНИЕ** *ср. мн.* нет — музей белеме (музейның төзелеше, бурычлары һәм эшләре турындагы белем).

**МУЗЕЕВЕ'ДНЫЙ** — к. музееведческий.

**МУЗЕЕВЕ'ДЧЕСКИЙ**—музей белеме...-ы; *музееведческое отделение* — музей белеме бүлеге.

**МУЗЕ'Й** *м.*— музей (тарих һәм сәнгать памятникларын, табигый-фәнни коллекцияләрне җыеп саклауны, халыкка күрсәтүне һәм шуның белән культура-агарту эшләрен алып баруны үзенә максат итеп куйган учреждение).

**МУЗЕ'ЙНЫЙ** —1. музей ...-ы; *музейное помещение* — музей бинасы; 2. музей өчен яраклы, музейга куярлык; *музейная картина* — музей өчен яраклы картина. ◇ **Музейная редкость** — бик сирәк очрый торган әйбер.

**МУЗИЦИ'РОВАТЬ** *несов.*— музыка уйнап вакыт үткәрү.

**МУ'ЗЫКА** *ж. мн.* нет —1. музыка; *история музыки* — музыка тарихы; 2. *разг.* оркестр; *полковая музыка* — полк оркестры; 3. *перен.* моңлылык; *музыка голоса* — тавышның моңлылыгы; 4. *перен.* эш (көйләнгән эш; җайга салынган эш); *испортил мне всю музыку* — минем бөтен эшемне бозды. ◇ **Музыка не та, или другая музыка** — бөтенләй башка эш, бөтенләй башка нәрсә, бөтенләй башкача.

**МУЗЫКА'ЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет —1. музыкальлек; аһәңлелек, моңлылык, моңлы булу; 2. музыкага сәләтле булу, музыкага сәләтлелек.

**МУЗЫКА'ЛЬНЫЙ** —1. музыка...-ы; *музыкальный инструмент* — музыка коралы; 2. музыкага сәләтле; *музыкальный мальчик* — музыкага сәләтле ир бала; 3. *разг.* моңлы, аһәңле, музыкаль; *музыкальный голос* — моңлы тавыш, музыкаль тавыш. ◇ **Музыкальная драма** *театр.*— музыкаль драма, музыкалы драма.

**МУЗЫКА'НТ** *м.*— музыкант; музыка остасы.

**МУЗЫКА'НТСКИЙ** *спец.*— музыкант...-ы; музыкантлар...-ы; *музыкантский гонорар* — музыкант гонорары.

**МУЗЫКОВЕ'Д** *м.*— музыка белгече, музыка белеме укытучысы.

**МУЗЫКОВЕ'ДЕНИЕ** *ср.*— музыка белеме (сәнгать фәнендә музыка тарихын һәм музыка теориясен өйрәнә торган бүлек).

**МУ'КА** *ж.*— газап, җәфа; *муки голода* — ачлык газаплары; *мука мне с тобой* — җәфа миңа синең белән. ◇ **Хождение по мукам** *книж.*— җәфа чигеп йөрү.

**МУКА'** *ж. мн.* нет — он; *ржаная мука* — арыш оны.

**МУКОМО'Л** *м. спец.*— тегермәнче, он тарттыручы.

**МУКОМО'ЛЬНИЧАТЬ** *несов. обл. спец.*— тегермәнче булып эшләү, он тарттыручы булып эшләү.

**МУКОМО'ЛЬНЫЙ** *спец.* — он...-ы; он тарту...-ы; *мукомольная мельница* — он тегермәне, он тарту тегермәне.

**МУКОМО'ЛЬНЯ** *ж. спец.*— тегермән.

**МУКОСЕ'Й** *м. спец.*— он иләүче.

**МУЛ** *м.*— качыр (ишәк белән бия кушылудан туган азман).

**МУЛА'Т** *м.*, **МУЛА'ТКА** *ж.*— мулат (ак тәнле белән кара тәнле кушылудан туган буын).

**МУЛЬТИПЛИКА'ТОР** I *м.*— мультипликатор (1. парогидравлик прессларга бик зур басым белән су кертә торган җайланма; 2. бер предметтан берьюлы күп рәсем төшерә торган күп объективлы фотографик камера).

**МУЛЬТИПЛИКА'ТОР** II *м.*— мультипликатор, мультипликация белгече.

**МУЛЬТИПЛИКАЦИО'ННЫЙ** *спец.* — мультипликацион; *мультипликационный фильм* — мультипликацион фильм.

**МУЛЬТИПЛИКА'ЦИЯ** *ж.*— мультипликация (1. хәрәкәтнең аерым моментларын күрсәтә торган рәсемнәр яки курчаклардан төшереп алынган кинокартина; 2. шундый картинаны эшләү ысулы).

**МУЛЯ'Ж** *м.*— муляж (1. *только ед.* балавыз, гипс һәм башкалардан модельләр, художество әйберләре кою; 2. шул юл белән эшләнгән әйбер, модель).

**МУЛЯЖИ'СТ** *м. спец.*— муляжист (муляж остасы).

**МУМИФИКА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *книж.*— к. мумифицировать, мумифицироваться.

**МУМИФИЦИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. книж.*— мумияләндерү, мумиягә әйләндерү (мәетне).

**МУМИФИЦИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. книж.*— мумияләнү, мумиягә әйләнү (мәетнең яки үләкснең черемичә кибүе).

**МУ'МИЯ** I *ж.*— мумия (1. борынгы халыкларда, бигрәк тә египетлыларда — бальзамлау юлы белән черетмичә сакланган мәет; 2. *науч.* черемичә саклана торган мәет; 3. *перен.* бик ябык кеше; аз хәрәкәтләнүчән кеше).

**МУ'МИЯ** II *ж.*— мумия (кызыл төстәге буяу).

**МУНДИ'Р** *м.*— мундир (формалы кием). ◇ **Картофель в мундире** *перен.*— чикмәнле бәрәңге, кабыгы белән пешерелгән бәрәңге, кабыклы бәрәңге.

**МУНДШТУ'К** *м.*—1. *спец.* (*у лошади*) авызлык; 2. *муз.* мундштук (тынлы музыка коралының авызга кабып уйный торган өлеше). 3. мундштук (тәмәке яки сигаретны кертеп тарту өчен); трубка сабы (тәмәке трубкасының авызга каба торган өлеше).

**МУНДШТУ'ЧИТЬ** *несов. спец.*— авызлыклау (атны).

**МУНИЦИПАЛИЗА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет— муниципализация (1. аерым кешеләр кулында булган җирләрнең яки йорт-каралты һәм башка корылмаларның хөкүмәт тара-

фыннан мәҗбүри рәвештә алынып, шәһәр яки авыл идарәсе карамагына бирелүе).

**МУНИЦИПАЛИЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. право* — муниципализация ясау, муниципализация үткәрү.

**МУНИЦИПАЛИТЕ'Т** *м. офиц. право* — муниципалитет (буржуаз илләрдә — шәһәр идарәсе).

**МУНИЦИПА'ЛЬНЫЙ** *офиц. право* — муниципаль; *муниципальные учреждения* — муниципаль учреждениеләр.

**МУНИЦИ'ПИЙ** *м. истор.* — муниципий (борынгы Римда — үз-үзен ирекле идарә итүгә тулы хокуклы булган шәһәр яки авыл общинасы).

**МУРА'** *ж. мн.* нет, *простореч.* — вак-төяк, ләкин мәшәкатьле эш.

**МУРАВА'** I *ж. мн.* нет — куе яшел үлән.

**МУРАВА'** II *ж. мн.* нет, *тех. обл.* — мурава, ялтыравык (кызыл балчыктан эшләнгән савытларны ялтырата торган лак).

**МУРАВЕ'Й** *м.* — кырмыска.

**МУРАВЕ'ЙНИК** *м.* — 1. кырмыска оясы, кырмыска түмгәге; 2. *перен.* кырмыска оясы күрер килеп тора торган халык төркеме).

**МУРА'ВИТЬ** *несов. спец.* — лаклау, ялтырату, мурава белән ялтырату (балчык савытны).

**МУРА'ВЛЕНЫЙ** *спец.* — мурава белән ялтыратылган; ялтыратылган; лакланган, лаклы; *муравленый изразец* — мурава белән ялтыратылган кирпеч.

**МУРА'ВЧАТЫЙ** I *обл.* — куе яшел үләнле, куе яшел үлән белән капланган; *муравчатый луг* — куе яшел үлән белән капланган болын.

**МУРА'ВЧАТЫЙ** II *обл.* и *устар.* — кара бөрчекле; бөрчекле; *муравчатый ситец* — бөрчекле ситсы.

**МУРАВЬЕ'Д** *м. зоол.* — кырмыскаашар.

**МУРАВЬИ'НЫЙ** — кырмыска...-ы; *муравьиная куча* — кырмыска оясы, кырмыска түмгәге.

**МУРА'Ш** *м. обл.* — вак кырмыска (өйләрдә яши торган).

**МУРА'ШКА** *ж.* — к. мураш. ◇ Мурашки бегают *разг.* — тән чымырдый.

**МУРЗА'** *м. дореврл.* — морза, мирза (татар дворяннары).

**МУРЛА'СТЫЙ** *простореч. вульг.* — тупас калын битле, шыксыз, ямьсез (битле).

**МУРЛО'** *ср. простореч. вульг. бран.* — тупас калын бит, шыксыз бит, ямьсез бит.

**МУРЛЫ'КАТЬ** *несов. разг.* — мырлау, мыраулау.

**МУРОВА'ТЬ** *несов. спец.* — муровать итү, таштан яки кирпечтән салу (балчык яки цемент белән сылап, таш яки кирпечтән берәр нәрсә салу).

**МУРЧА'ТЬ** *несов. обл.* — к. ворчать.

**МУСКА'Т** *м. мн.* нет — 1. мөшкәт чикләвеге; 2. мускат (а. йөзем сорты; б. шул йөземнән ясалган кызыл аракы).

**МУСКА'ТНЫЙ** — мөшкәт...-ы; *мускатное масло* — мөшкәт мае.

**МУ'СКУЛ** *м.* — мускул.

**МУСКУЛАТУ'РА** *ж. мн.* нет — мускулатура, мускуллар.

**МУ'СКУЛИСТЫЙ** *разг.* — таза мускуллы; нык мускуллы; *мускулистые руки* — таза мускуллы куллар.

**МУ'СКУС** *м. мн.* нет — мускус, миск (ата кабарганың аталык бизләреннән алына торган хуш исле матдә).

**МУСЛИ'Н** *м. мн.* нет — муслин (мамыктан, йоннан яки ефәктән тукылган җиңел, юка, йомшак тукыма).

**МУСЛИ'НОВЫЙ** — муслин..., муслиннан тегелгән; *муслиновая ткань* — муслин тукыма; *муслиновое платье* — муслин күлмәк.

**МУ'СЛИТЬ** *несов. простореч.* — 1. төкерекләү; *муслить нитку* — җепне төкерекләү (энә саплаганда); 2. төкереп пычрату, төкерек белән пычрату.

**МУ'СЛИТЬСЯ** *несов. простореч. страд.* — 1. төкерекләнү (җеп); 2. төкерекләп пычратылу, төкерек белән пычратылу.

**МУСО'ЛИТЬ** *несов. простореч.* — 1. к. муслить; 2. *перен.* мәгънәсез озак тикшерү, озак маташу; *мусолить какой-нибудь вопрос* — нинди дә булса берәр мәсьәләне озак тикшерү, очына чыга алмау.

**МУСО'ЛИТЬСЯ** *несов. простореч. страд.* — 1. к. муслиться; 2. *перен.* мәгънәсез озак тикшерелү, озак каралу.

**МУ'СОР** *м.* — чүп, чүп-чар.

**МУ'СОРИТЬ** *несов. разг.* — чүпләү.

**МУ'СОРНЫЙ** — чүп...-ы; *мусорная куча* — чүп өеме.

**МУ'СОРЩИК** *м.*, **МУ'СОРЩИЦА** *ж. спец.* — чүп түгүче.

**МУСС** *м. кулин.* — мусс (җиләк-җимеш суының күбеге — татлы ашамлык).

**МУССИ'РОВАТЬ** *несов.* — 1. *спец.* күбекләндерү; *муссировать вино* — кызыл аракыны күбекләндерү; 2. *спец.* (*пениться*) күбекләнү; 3. *перен.* тарату; *муссировать слухи* — хәбәрләр тарату (арттырып, күпертеп, инәдән дөя ясап сөйләү).

**МУССИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд* — 1. *спец.* күбекләндерелү; 2. *перен.* таратылу (хәбәр).

**МУССО'Н** *м. геогр.* — муссон (кыш көнө диңгезгә, җәй көне диңгездән коры җиргә таба исә торган җил).

**МУСТ** *м. мн.* нет, *спец.* — муст (ачып җитмәгән татлы кызыл аракы).

**МУСУЛЬМА'НИН** *м.* — мөселман.

**МУСУЛЬМА'НСКИЙ** — мөселман...-ы, ислам...-ы; *мусульманская религия* — мөселман (ислам) дине.

**МУСУЛЬМА'НСТВО** *ср. мн.* нет — 1. мөселманлык; 2. *собир.* мөселманнар.

**МУТА'ТОР** *м. науч.* — мутатор (электр тогын өзү һәм ялгау приборы).

**МУТА'ЦИЯ** *ж. науч.* — мутация (1. малайларның егет булып җиткәндә тавышлары үзгәрүе, калынаюы; 2. биология фәнендәге идеалистик морганизм агымы карашынча, организмда кинәт үзгәрешләр сарлыкка килеп, аларның нәселдән нәселгә күчүе).

**МУТИ'ТЬ** *несов.* — 1. болгату; *мутить*

*воду* — суны болгату; 2. *перен.* томалау, карангылау; *любовь мутит моё воображение* (Пушкин) — мәхәббәт минем хыялымны томалый; 3. *(подстрекать)* котырту, болгату; 4. *безл. разг.* күңел болгану; *меня мутит* — күңелем болгана.

**МУТИ'ТЬСЯ** *несов.* —1. болгану; *вода мутится* — су болгана; 2. *перен.* томалану, чуалу, караңгылану; *ум мутится* — аңым томалана.

**МУТНЕ'ТЬ** *несов.*— болганчыклану.

**МУ'ТНОСТЬ** *ж. мн.* нет —1. болганчыклык, болганчык булу; *мутность воды* — суның болганчыклыгы; 2. к. муть.

**МУ'ТНЫЙ** — 1. болганчык; *мутная вода* — болганчык су; 2. тонык; үтә күренми торган; *мутное стекло* — тонык пыяла; 3. *поэт.* томанлы; *мутное небо* — томанлы күк йөзе; 4. *перен. (помраченный, смутный)* томанлы, чуалчык, караңгы. ◇ **В мутной воде рыбу ловить** — к. ловить.

**МУТО'ВКА** *ж.*—1. болгаткыч, тугылагыч; 2. *бот.* божра, тезмә, такыя (үсемлекләрдә).

**МУ'ТОРНО: муторно на душе** — эч поша.

**МУ'ТОРНЫЙ** — күңелсез, эч пошыргыч, мәгънәсез, күңелгә ошамый торган.

**МУТУ'ЗИТЬ** *несов. просторен.* — дөмбәсләү, тукмау, кыйнау.

**МУТЬ** *ж. мн.* нет — *(осадок)* юшкын, утырма, куерык.

**МУ'ФЕЛЬ** *м. горн. хим.*— муфель (керамик һәм фарфор әйберләр кыздыру өчен мичкә куелган камера).

**МУ'ФЕЛЬНЫЙ** *горн. хим.*— муфельле; *муфельная печь* — муфельле мич.

**МУФЛО'Н** *м.*— муфлон (кыргый сарык).

**МУ'ФТА** I *ж.*— муфта (хатын-кызларның мехтан тегелгән кул киеме).

**МУ'ФТА** II *ж. тех.* — муфта (машина частьларын үзара тоташтыру өчен кулланыла торган кыска гына тимер көпшә).

**МУ'ФТИЙ** *м.* — мөфти (мөселманнарда дини идарә башлыгы).

**МУ'ХА** *ж.*— чебен. ◇ **Быть с мухой (под мухой)** *разг. шутл.*— исерек булу. **Муху зашибить** — аракы эчү. **Мухи не обидит** — к. обидеть. **Делать из мухи слона** — төймәдән дөя ясау, төймәне дөя итү.

**МУХОЛО'ВКА** *м.*— 1. *спец.* чебен үтергеч (җайланма); 2. *зоол.* чебенче (кош); 3. *бот.* чебенчел (үс.).

**МУХОМО'Р** *м* —1. *бот.* мухомор, чебен гөмбәсе; 2. *спец.* мухомор (чебен агуы сөртелгән кәгазь).

**МУХО'РТИК** *м. обл. шутл.*— кечкенә буйлы кеше.

**МУХОЯ'Р** *м. устар.*— к. муар.

**МУЧЕ'НИЕ** *ср.*— газап, җәфа, газаплану, җәфалану.

**МУ'ЧЕНИК** *м.*, **МУ'ЧЕНИЦА** *ж.*— җәфа күрүче, газап чигүче, җәфаланучы, газапланучы.

**МУ'ЧЕНИЧЕСКИЙ** — җәфа чиккән; газаплы; *у него мученический вид* — ул җәфа чиккән чырайлы; *мученическая смерть* — газаплы үлем.

**МУЧИ'ТЕЛЬ** *м.*—җәфалаучы, газаплаучы, интектерүче.

**МУЧИ'ТЕЛЬНЫЙ** — интектерә торган, җәфалы, газаплы, интектергеч; *мучительный кашель* — интектерә торган ютәл, интектергеч ютәл.

**МУ'ЧИТЬ** *несов. разг.*— җәфалау, интектерү, газаплау, йөдәтү; *не мучь меня* — йөдәтмә мине, газаплама мине.

**МУ'ЧИТЬСЯ** *несов. разг.*— җәфалану, интегү, газаплану, йөдәү.

**МУЧНИ'К** *м. спец.*— он сатучы.

**МУЧНИ'СТЫЙ** — ончыл, онлы, крахмаллы.

**МУЧНО'Й** —1. он...-ы; *мучной мешок* — он капчыгы; 2. камыр...-ы; *мучное блюдо* — камыр ашы.

**МУ'ШКА** I *ж.*—1. к. муха; 2. миң (ясалма һәм табигый).

**МУ'ШКА** II *ж. спец.*— мушка (винтовка көпшәсе очында төзәп ату өчен эшләнгән чыгынты).

**МУШИ'НЫЙ** — чебен...-ы; *мушиный яд* — чебен агуы; *мушиный укус* — чебен тешләве.

**МУШКЕ'Т** *м. истор.*— мушкет (борынгы мылтык төре).

**МУШКЕТЁР** *м.*— мушкетёр (1. борынгыда — мушкет белән коралланган җәяүле солдат; 2. Франциядә — гвардия кавалериясендә хезмәт итүче дворян).

**МУШМУЛА'** *ж. мн.* нет — мушмула, башмала (көньякта үсә торган куак һәм аның җимеше).

**МУШТРА'** *ж. мн.* нет, *неодобр.*— муштра, таяк дисциплинасы (1. буржуаз илләрдә — хәрби өйрәтү системасы; 2. механик дисциплинага нигезләнгән тәрбия системасы).

**МУШТРОВА'ТЬ** *несов. неодобр.*— муштровать итү, муштра белән өйрәтү, таяк дисциплинасы белән өйрәтү.

**МУШТРО'ВКА** *ж. мн.* нет, *неодобр.*— к. муштровать.

**МУЩИ'НА** *м.*— к. мужчина.

**МУЭДЗИ'Н** *м.*— мәзин.

**МЦЫ'РИ** *м. нескл.*— мцыри, монах.

**МЧАТЬ** *несов.*—1. чаптырып алып бару, шәп алып бару, бик тиз алып бару; 2. *разг.* к. мчаться.

**МЧА'ТЬСЯ** *несов.*— бик тиз бару; шәп бару, очкан кебек бару; чабу; *поезд мчится* — поезд бик тиз бара; *куда ты мчишься?* — син кая чабасың?

**МША'НЫЙ** *обл.*— мүкләнгән, мүкле, мүк үскән; *мшанов болото* — мүк үскән сазлык, мүкле сазлык.

**МШИ'СТЫЙ** — мүкле, мүк баскан, мүк белән капланган.

**МШИТЬ** *несов.*— сүсәртү; *мшить верёвку* — бауны сүсәртү.

**МШИ'ТЬСЯ** *несов.*— сүсәрү; *верёвка от трения мшится* — бау ышкылып сүсәрә.

**МЩЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.*—1. үч алу; 2. үч.

**МЫ** *местоим.* — без.

**МЫ'ЗА** *ж.*— мыза, утар, усадьба (Эстониядә һәм Финляндия белән чиктәш ра-

йоннарда үзенең хужалыгы, каралтылары булган аерым йорт, шәһәр тышындагы усадьба).

**МЫ'ЗГАТЬ** *несов. простореч.*— пычрату, таушалдыру (киемне).

**МЫ'КАТЬ** *несов. простореч.*—1. тарау, тәрәшләү (житенне); 2. язу (йонны). ◇ **Горе мыкать** *разг.*— интегү, газап чигү, жәфа күрү, михнәт чигү, нужа күреп йөрү, каңгырып йөрү.

**МЫ'КАТЬСЯ** *несов. простореч. разг.*— йортсыз-җирсез газап чигеп йөрү, интегү, нужа чигеп йөрү; *устал я мыкаться* — йортсыз-җирсез йөреп арыдым мин; *мыкаться по свету* — өзлексез газап чигеп йөрү.

**МЫ'ЛИТЬ** *несов.*—1. сабынлау; *мылить материю* — материяне сабынлау; 2. сабын белән күбекләндерү; *мылить воду* — суны сабын белән күбекләндерү.

**МЫ'ЛИТЬСЯ** *несов.*—1. сабынлану; 2. күбекләнү, чыгу; *это мыло хорошо мылится* — бу сабын яхшы күбекләнә, бу сабын яхшы чыга; 3. *страд.* күбекләнделү.

**МЫ'ЛКИЙ** — яхшы күбекләнә торган, яхшы чыга торган; *мылкое мыло* — яхшы күбекләнә торган сабын.

**МЫ'ЛКОСТЬ** *ж. мн.* нет, *спец.*— яхшы күбекләнүчәнлек, яхшы күбекләнү.

**МЫ'ЛО** *ср.*—1. сабын; 2. *только ед.* ак күбек (кызу чапкан атта).

**МЫЛОВА'Р** *м.*— сабын кайнатучы (сабын кайнату белгече).

**МЫЛОВАРЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — сабын кайнату.

**МЫЛОВА'РЕННЫЙ** — сабын...-ы; сабын кайнату...-ы; сабын кайната торган; *мыловаренный завод* — сабын заводы; *мыловаренный чан* — сабын кайната торган чан.

**МЫ'ЛЬНИЦА** *ж.*— сабын савыты.

**МЫ'ЛЬНЫЙ**—1. сабын...-ы; *мыльный раствор* — сабын эремәсе; 2. сабынлы; *мыльный клей* — сабынлы жилем. ◇ **Мыльный пузырь** —1. сабын куыгы (сабынлы суга салам манчып, икенче башыннан өргәч кабара торган куык); 2. *перен.* коры куык (нигезсез нәрсә турында). **Мыльный корень** *бот.*— сабын үләненең тамыры.

**МЫ'ЛЬЩИК** *м. обл.*— к. банщик.

**МЫ'МРА** *ж. обл. презрит.*— күңелсез кеше, сытык чырайлы кеше, кызыксыз кеше.

**МЫС** *м.*—1. мыс, борын (диңгезгә, күлгә яки елгага очлаеп кергән коры җир). 2. *перен.* очлаеп кергән урын; *поля здесь образуют мыс, окружённый лесом* — биредә кырлар урманга очлаеп кергәннәр.

**МЫ'СЛЕННЫЙ** *книж.*— фикердәге, уйдагы, баштагы.

**МЫ'СЛИМЫЙ**— 1. *книж. устар.* уйланылган, уйга китерелгән; 2. булуы мөмкин булган; башка сыйдырырга мөмкин булган; *где ещё мыслимы подобные вещи!*— шушындый нәрсәләр тагын кайда булырга мөмкин!

**МЫСЛИ'ТЕЛЬ** *м.*— фикер иясе, акыл иясе, тирән акыллы кеше, зур акыл иясе.

**МЫСЛИ'ТЕЛЬНЫЙ** *науч.* — фикерләү ...-ы; уйлау...-ы; акыл йөртү...-ы; *мыслительная способность* — фикерләү (уйлау) сәләте.

**МЫ'СЛИТЬ** *несов. книж.* — фикерләү, фикер йөртү, уйлау, уй йөртү. ◇ **Много мыслить о себе** — үзе турында күпне уйлау; борын күтәрү.

**МЫСЛИ'ШКА** *ж. разг. пренебр.*— әһәмиятсез фикер, фикер кисәге, юк-бар акыл.

**МЫСЛЬ** *ж.*—1. фикерләү, фикер йөртү; *сила человеческой мысли* — кешенең фикерләү көче, фикер йөртү көче; 2. фикер, идея; *интересная мысль* — кызыклы фикер, кызыклы идея; 3. уй; *мысль о сыне* — ул (ым) турындагы уй; 4. *только мн.* фикер, караш; *мы с вами одних мыслей* — без сезнең белән бер фикердәге кешеләр, бер караштагы кешеләр.

**МЫ'СЛЯЩИЙ** *книж.*—1. фикер йөртә белә торган; уйлый белә торган; *мыслящий реалист* — фикер йөртә белә торган реалист; 2. фикерләүче, уйлаучы, тирән уйлаучы, уйга чумган; *мыслящий вид* — уйга чумган кыяфәт.

**МЫТ** I *м. мн.* нет, *вет.*— сака, тычкан авыруы (атларда була торган йогышлы авыру).

**МЫТ** II *м. мн.* нет, *истор.*— мыт, пошлина (борынгы Русьта — шәһәр капкалары аша товар яки мал үткәргәндә алынган пошлина).

**МЫТА'РИТЬ** *несов. разг.*— тормыш газабы күрсәтү, йөдәтү, интектерү, газаплау.

**МЫТА'РИТЬСЯ** *несов. разг.*— газап күрү, йөдәү, жәфалану, газап чигү, нужа күрү, михнәт чигү.

**МЫТА'РСТВО** *ср.*— газап, жәфа, михнәт.

**МЫТЬ** *несов.*— юу. ◇ **Рука руку моет**— 1. кул кулны юа; 2. *перен.* карга күзен карга чукымый.

**МЫ'ТЬСЯ** *несов.*—1. юыну; *мыться в ванне* — ваннада юыну; 2. *страд.* юылу; *бельё моется в корыте* — кер ялгашта (тагаракта) юыла (керне тагаракта юалар).

**МЫЧА'ТЬ** *несов.*—1. *(о корове, быке)* мөңрәү, мөгрәү; 2. *перен. разг. фам. (о человеке)* мыгырдау.

**МЫША'СТЫЙ** *спец.*— соры (ат төсе).

**МЫШЕЛО'В** *м.*— тычкан тотучы.

**МЫШЕЛО'ВКА** *ж.*— тычкан тәбесе, капкын.

**МЫ'ШЕЧНЫЙ** *анат.*— мускул...-ы; *мышечная боль* — мускул авыртуы.

**МЫ'ШИЙ** *разг.*— к. мышиный.

**МЫШИ'НЫЙ** —1. тычкан...-ы; *мышиный помёт* — тычкан тизәге; 2. *спец.* к. мышастый.

**МЫ'ШКА** *ж.*—1. тычкан; 2. *старин.* мускул.

**МЫШКОВА'ТЬ** *несов. спец.*— тычкан тоту, тычкан аулау (жәнлекләр турында); *мышкующая лиса* — тычканнар тотучы төлке.

**МЫ'ШЛЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — уйлау, фикерләү, фикер йөртү.

**МЫШО'НОК** *м.* (*мн.* мышата) — тычкан баласы.

**МЫ'ШЦА** *ж.*—1. *анат.* мускул; 2. *книж. поэт. устар.* кул.

**МЫШЬ** *ж.*— тычкан. ◇ **Летучая мышь**— ярканат.

**МЫШЬЯ'К** *м. мн.* нет — мышьяк (1. *хим.* агулы химик элемент; 2. *мед. апт.* мышьяктан ясалган дару).

**МЫШЬЯКО'ВЫЙ**—1. мышьяк...-ы; *мышьяковый препарат* — мышьяк препараты; 2. мышьяклы; *мышьяковые соли* — мышьяклы тозлар.

**МЫШЬЯ'ЧНЫЙ** *мед. апт.*— мышьяклы; *мышьячные пилюли* — мышьяклы пилюлялар, мышьяклы дарулар.

**МЫ'ЩЕЛКА** *ж.* и *разг.* **МЫ'ЩЕЛОК** *м. анат.*— бүлтәймә (скелеттагы сөякләрнең очларында мускулларны беркетү яки икенче сөяк белән тоташу хезмәтен үти торган калын чыгынты).

**МЭР** *м.*— мэр (кайбер буржуаз илләрдә— муниципалитет башында торучы, шәһәр башлыгы).

**МЭ'РИЯ** *ж.*— мэрия (Франциядә — муниципалитет идарәсе).

**МЮЛЬ** *м.*, **МЮЛЬ-МАШИ'НА** *ж. тех.*— мюль-машина, эрләү машинасы.

**МЮ'ЛЬЩИК** *м. спец.*— мюль-машинада эшләүче, эрләү машинасында эшләүче.

**МЮРИ'Д** *м. истор.*— мөрит.

**МЯ'ГКИЙ** —1. йомшак; *мягкий хлеб* — йомшак икмәк; 2. *лингв.* нечкә; *мягкие согласные* — нечкә тартыклар. ◇ **Мягко выражаясь** *разг.*, *иногда ирон. ввод. сл.*— йомшак итеп әйткәндә. **Мягкая зима** — жылы кыш, йомшак кыш. **Мягкий знак (буква)** — нечкәлек билгесе (мәсәлән, февраль сүзендә).

**МЯГКОСЕРДЕ'ЧИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.*— йомшак күңеллелек, миһербанлылык, шәфкатьлелек.

**МЯГКОСЕРДЕ'ЧНЫЙ** *книж.*— йомшак күңелле, миһербанлы, шәфкатьле.

**МЯ'ГКОСТЬ** *ж. мн.* нет — йомшаклык; *мягкость воды* — суның йомшаклыгы.

**МЯГКОТЕ'ЛОСТЬ** *ж. мн.* нет —1. йомшак тәнлелек, йомшак тәнле булу; 2. йомшак характерлылык, мәми авызлык.

**МЯГКОТЕ'ЛЫЙ** —1. йомшак, итләч, йомшак тәнле; *мягкотелая груша* — йомшак (итләч) груша; 2. *перен.* йомшак, характерсыз, мәми авыз (кеше).

**МЯГКОШЁРСТНЫЙ** *спец.*— йомшак йонлы; *мягкошёрстные овцы* — йомшак йонлы сарыклар.

**МЯГЧИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж. мед.*— йомшарту ...-ы, йомшарткыч; *мягчительные средства* — йомшарткыч средстволар, йомшарту чаралары.

**МЯГЧИ'ТЬ** *несов.*— йомшарту.

**МЯКИ'НА** *ж. мн.* нет, *с.-х.*— кибәк.

**МЯКИ'ННЫЙ** —1. *с.-х.* кибәкле; *мякинный корм* — кибәкле азык; 2. *перен. просторен.* буш, кибәк..., аңгыра; *мякинная голова* — кибәк баш, аңгыра баш.

**МЯ'КИШ** *м. мн.* нет — ипи йомшагы.

**МЯ'КЛЫЙ** *обл.*— йомшарган, изелгән, изрәгән; *мяклое яблоко* — йомшарган алма.

**МЯ'КНУТЬ** *несов.*—1. йомшару; *сухарь мякнет в молоке* — сохари сөттә йомшара; 2. *перен. фам. пренебр.* изрәү, изелеп төшү; бөтенләй йомшарып китү, җебеп калу; *он мякнет от одного ласкового слова* — ул бер ягымлы сүздән изелеп төшә.

**МЯ'КОТЬ** *ж. мн.* нет —1. сум ит (сөяксез ит); 2. җимеш йомшагы.

**МЯ'КУШ** *м. мн.* нет, *обл.*— к. мякиш.

**МЯ'ЛКА** *ж.*—1. *тех.* к. льномялка; 2. *тех.* мялка, тире йомшарткыч (машина); 3. *обл. шутл.* авыз.

**МЯ'ЛО** *ср. тех. устар.* и *обл.*— к. мялка.

**МЯ'ЛЬНЯ** *ж. спец.*— талку урыны.

**МЯ'ЛЬЩИК** *м. спец.*— талкучы (эшче).

**МЯ'МЛИТЬ** *несов. разг. пренебр.*—1. әкрен сөйләү, ялкауланып сөйләү, иренеп сөйләү; авызда ботка пешерү; 2. *перен.* сузып эшләү, озак эшләү (эшне).

**МЯ'МЛЯ** *ж. разг. пренебр.* — пешмәгән, мәми авыз.

**МЯСИ'СТЫЙ** —1. итләч, итле; 2. *разг.* симез.

**МЯСНА'Я** *в знач. сущ.*— ит кибете, ит магазины.

**МЯСНИ'К** *м.*— ит сатучы, итче.

**МЯСНО'Е** *в знач. сущ.*— итле аш, итле азык.

**МЯСНО'Й**—1. ит...-ы; *мясная торговля*— ит сәүдәсе; 2. итле; *мясной суп* — итле аш.

**МЯ'СО** *ср. мн.* нет — ит. ◇ **Пушечное мясо** — туп ите (империалистлар файдасы өчен сугышка җибәрелгән солдатлар). **Вырвать пуговицу с мясом** — сәдәпне материясе белән өзеп алу.

**МЯСОЕ'Д** *м.*—1. христианнарда ит ашарга ярый торган вакыт; 2. ит ашаучы, ит белән тукланучы.

**МЯСОЗАГОТО'ВКА** *ж. спец.*— ит хәзерләү, дәүләткә ит тапшыру (сату).

**МЯСОКОМБИНА'Т** *м.*— ит комбинаты.

**МЯСОРУ'БКА** *ж. тех.*— мясорубка, ит машинасы (ит тарттыра торган машина).

**МЯСОСОВХО'З** *м.*— итчелек совхозы (сугым өчен терлек үрчетү совхозы, ит өчен терлек асрау совхозы).

**МЯСТИ'СЬ** *несов. книж. устар.*— тәшвишләнү, тынгысызлану, тынычсызлану.

**МЯСЦО'** *ср. мн.* нет, *разг.*— ит.

**МЯ'ТА** *ж. мн.* нет, *бот.*— бөтнек (үс.)

**МЯТЕ'Ж** *м.*— фетнә, чуалыш, баш күтәрү (хөкүмәткә каршы).

**МЯТЕ'ЖНИК** *м.*— фетнәче, чуалыш тудыручы, баш күтәрүче.

**МЯТЕ'ЖНЫЙ** *книж.*—1. фетнәче...; баш күтәрүче...; фетнәчеләр...-ы; *мятежные войска* — фетнәче гаскәрләр; 2. тынычсыз, тынгысыз; *мятежный характер* — тынгысыз характер.

**МЯ'ТЛИК** *м. мн* нет, *с.-х.*— йонча (мал өчен яхшы азык дип исәпләнә торган кыяклы үсемлек).

**МЯ'ТНЫЙ** —1. бөтнек...-ы; *мятный запах* — бөтнек исе; 2. бөтнек кушып пе-

шерелгән; *мятный пряник* — бөтнек кушып пешерелгән пряник.

**МЯТЬ** *несов.*—1. изү; *мять глину* — кызыл балчык изү; 2. йомарлау; *мять бумагу* — кәгазьне йомарлау; 3. таушалдыру, борчу; *мять платье* — күлмәкне таушалдыру; 4. талку; *мять лён* — җитен талку; 5. бөгү; *мять железо* — тимерне бөгү; 6. таптау; *мять траву* — үләнне таптау.

**МЯ'ТЬСЯ** *несов.*—1. *страд.* уылу; *кожа мнётся для размягчения* — тире йомшарту өчен уыла (тирене йомшарту өчен уалар); 2. таушалу, борчылу, бөгәрләнү; *шляпа мнётся* — эшләпә таушала; *платье мнётся* — күлмәк бөгәрләнә; 3. изелү; *глина хорошо мнётся* — кызыл балчык яхшы изелә; 4. *перен. разг. фам.* икеләнү, кыюсызланып тору.

**МЯУ'КАТЬ** *несов.*— мыяулау.

**МЯУ'ЧИТЬ** *несов. обл.*— к. мяукать.

**МЯЧ** *м.*— туп.

# Н

**НА I** *предлог. с вин. пад.*—1. ...-га, ...-га таба, ...-га каршы; *выйти на улицу* — урамга чыгу; *лечь на диван* — диванга яту; *двигать войска на неприятеля* — гаскәрләрне дошманга каршы алып бару; *на счастье вблизи никого не было* — бәхеткә каршы, якында бер кеше дә юк иде; *ответ на вопрос* — сорауга җавап; 2. ...-га, ...-ны; *заседание назначено на вечер* —утырыш кичкә билгеләнгән; *увидеться на другой день* — икенче көнне очрашу; *разделить на три* — өчкә бүлү; *помножить на два* — икегә тапкырлау; *опоздать на пять минут* — биш минутка соңга калу; *старше на пять лет* — биш яшькә олы; *на такие дела я не гожусь* — мин мондый эшләргә ярамыйм; *хромать на одну ногу* — бер аякка аксау; *слово кончается на согласный* — сүз тартык авазга бетә (сүзнең азагында тартык аваз); 3. ...-га, ...-лык; *одолжить книгу на несколько дней* — китапны берничә көнгә алып тору; *этой работы ещё на целый год* — бу эш тагы бер елга (җитәр), бу эш тагы бер еллык; *отпуск на месяц* — бер айлык (айга) отпуск; *купить ягод на два рубля* — ике сумлык җиләк сатып алу; *прославиться на весь мир* — бөтен дөньяга танылу, дан чыгу; *комната на двух человек* — ике кешелек бүлмә; *обед на девять персон* — тугыз кешелек аш; 4. ...-га, ...өчен, ...-лык; *деньги на ремонт* — ремонтка (ремонтлык) акча; *материя на пальто* — пальтолык материя; *взять на воспитание* — тәрбиягә алу; *один работает на всю семью* — бөтен семьясы өчен бер ялгызы эшли; *на всех не угодишь* — бөтен кешегә ярый алмассың. ◇ **На что (уж)** *разг.*— никадәр... булса да, нихәтле... булса да; *на что уж он скупой, и то дал пять рублей* — ул никадәр саран булса да, биш сум бирде. **На свежую голову** — саф баштан, саф баш белән. **Мастер на все руки** — һәр эшкә оста, кулыннан килмәгән эше юк, һәртөрле эш кулыннан килә. **На безрыбье и рак рыба** — ит юкта үпкә тансык. **Испытание на прочность** — ныклыгын сынау. **Подарить на память**—истәлек итеп бирү. **Говорить на память** — яттан сөйләү. **Глух на одно ухо** — бер колагы ишетми.

**НА II** *предлог с предл. пад.*—1. ...-да, ...өстендә; *на улице большое движение* — урамда зур хәрәкәт; *карта лежит на шкафу* — карта шкаф өстендә ята; *на этих днях* — бу көннәрдә; *на работе* — эштә; *жарить на масле* — майда кыздыру; *стоять на страже* — сакта тору; 2. ...-ганда, ...-ган вакытта; *на бегу* — йөгереп барганда, йөгереп барган вакытта, йөгереп барган килеш; 3. ...алдында, ...каршында; *на людях*—халык алдында, кешеләр каршында; *на глазах* — күз алдында; 4. ...-лы; *коляска на рессорах* — рессоралы (сиртмәле) арба; *матрац на пружинах* — пружинлы матрац; *обувь на двойной подошве* — ике кат олтанлы аяк киеме; 5. ...-да, ...белән; *ехать на пароходе* — пароход белән бару, пароходта бару; *играть на рояле* — рояльдә уйнау; 6. ...-да; *изъясняться на французском языке* — француз телендә сөйләшү; 7. ...-лы; *мазь на вазелине* — вазелинлы мазь; 8. ...өчен; *благодарю вас на добром слове* — яхшы сүзегез өчен сезгә рәхмәт. ◇ **Он много потерял на этом деле**—бу эш аңар кыйммәткә төште. **Стоять на часах** — сакта тору. **Тоска на сердце** — эч поша. **Пальто на вате** — сырган пальто.

**НА III** *частица разг.*— мә; *на, возьми* — мә, ал. ◇ **Вот тебе на!** — менә сиңа кирәк булса! **На поди** — менә тагы; *на поди, кричать начал* — менә тагы, кычкыра башлады.

**НА IV** *частица:* **какой ни на есть** *простореч.*— нинди дә булса бер; *может, вы думаете, что я какой ни на есть свинья?* — сез әллә мине нинди дә булса бер дуңгыз дип уйлыйсызмы? **Что ни на есть** — менә дигән; *товар что ни на есть лучший* — менә дигән товар.

**НАБА'Б**— к. набоб.

**НАБА'ВИТЬ** *сов.*— өстәү, арттыру.

**НАБА'ВКА** *ж. разг.*—1. *(действие)* к. набавить; 2. өстәмә.

**НАБАВЛЯ'ТЬ** *несов.*— к. набавить.

**НАБАВЛЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.*—өстәлү, арттырылу.

**НАБА'ВОЧНЫЙ** *разг.*— өстәмә, өстәлә торган, өстәлгән.

**НАБА'ВЩИК** *м. спец.*— набавщик, хак өстәүче, хакны арттыручы (мәсәлән, аукционда).

**НАБА'ГРИВАТЬ** *несов.*— к.набагрить.

**НАБА'ГРИТЬ** *сов. спец.* — багор белән тоту, багор белән тотып алу (берникадәр балык тоту турында).

**НАБАЛАГУ'РИТЬ** *сов. простореч.* — мәзәк сөйләп алу, бик күп мәзәк сөйләп ташлау.

**НАБАЛАМУ'ТИТЬ** *сов. простореч.* — дөнья бозу, дөнья бутау.

**НАБАЛДА'ШНИК** *м.* — сакма, таяк чукмары, таяк башы (таяк башына киертелгән яки ясалган тотка).

**НАБАЛОВА'ТЬ** *простореч.* — 1. иркәләп бозу; *набаловать ребёнка* — баланы иркәләп бозу; 2. шаянлыклар эшләп алу, шаянлыклар эшләп ташлау, шаяра торгач берәр зыян китерү.

**НАБАЛОВА'ТЬСЯ** *сов. разг. фам.* — туйганчы шаяру, шаярып тую.

**НАБА'ЛТЫВАТЬ** *несов. разг.* — 1. болгату; 2. (*о яйце*) тугылау.

**НАБАЛЬЗАМИ'РОВАТЬ** *сов.* — бәлзәмләү (мәетләрне черүдән саклау өчен махсус матдәләргә туендыру).

**НАБАРАХЛИ'ТЬ** *сов. простореч. вульг.* — юк-барны сөйләп ташлау; юк-барны эшләп ташлау; сәбәпсез шау-шу куптару.

**НАБАРЫ'ШНИЧАТЬ** *сов. простореч. устар.* — вак-төякләр алып сатудан файда итү; атлар белән сәүдә итеп файда алу.

**НАБА'Т** *м.* — набат, чаң кагу; *звуки набата* — набат (чаң кагу) тавышлары. ◇ Бить в набат — 1. чаң кагу (берәр бәла, куркыныч турында хәбәр итеп яки ярдәм сорап чаң кагу); 2. *перен. книж.* тавыш куптару; шау-шу куптару; *газеты бьют в набат* — газеталар тавыш куптардылар.

**НАБА'ТНЫЙ** — набат...-ы, чаң...ы; *набатный колокол* — набат чаны; *набатные звуки* — чаң тавышы.

**НАБАТРА'ЧИТЬ** *сов. обл. устар.* — батрак булып эшләп алу (мәсәлән, акча).

**НАБЕ'Г** *м.* — һөҗүм; баскын; *в жарких странах обезьяны производят набеги на хлебные поля* — эссе якларда маймыллар иген кырларына һөҗүм итәләр; *набег кочевых орд* — күчмә урдаларның баскыны (яу булып басып керүе).

**НАБЕ'ГАТЬ** *сов. разг.* — йөгерә-йөгерә үзеңә зыян китерү, күп йөгереп йөреп үзеңә зыян китерү; *набегать себе болезнь сердца* — күп йөгереп йөреп йөрәк авыруы алу.

**НАБЕГА'ТЬ** *несов.* — 1. к. набежать; 2. *безл. порт.* җыерылып тору; *около ворота немножко набегает* — яка тирәсендә аз гына җыерылып тора.

**НАБЕ'ГАТЬСЯ** *сов. разг.* — йөгерә-йөгерә арып бетү, йөгереп йөри-йөри ару; туйганчы йөгерү, йөгереп тую; *я до того захлопотался и набегался, что даже заболел* — мин эш артыннан йөгереп йөри-йөри шулкадәр арыдым, хәтта авырый башладым.

**НАБЕДОКУ'РИТЬ** *сов. простореч.* — азынып ташлау, азынып зыян китерү, шаярып зыян китерү, шукланып бәла-каза китерү.

**НАБЕЖА'ТЬ** *сов.* — 1. бәрелү, барып бәрелү; килеп бәрелү; менү; *волна набежала на берег* — дулкын ярга килеп бәрелде; дулкын ярга менде; *сани набежали на лошадь* — чана атка барып бәрелде; 2. каплау; *тучки набежали на луну* — айны болытлар каплады; 3. җыелу, йөгереп килеп җыелу; *народ набежал со всех сторон* — төрле яктан халык йөгереп килеп җыелды; 4. *разг. фам.* җыелу, өсталү; *набежала пеня* — пеня җыелган, пеня өсталгән.

**НАБЕЗОБРА'ЗНИЧАТЬ** *сов. разг.* — тәртипсезлекләр эшләп ташлау, әшәкелекләр эшләп ташлау.

**НАБЕКРЕ'НЬ** *нареч. разг.* — кырын салып, кыңгыр салып; *шапка набекрень* — бүрекне кырын салып. ◇ Мозги набекрень *простореч. шутл.* — җиңел акыллы, тиле-миле, иләс-миләс.

**НАБЕЛИ'ТЬ** *сов.* — к. белить.

**НАБЕЛИ'ТЬСЯ** *сов.* — к. белиться.

**НА'БЕЛО'** *нареч.* — акка; *переписать набело* — акка күчереп язу.

**НА'БЕРЕЖНАЯ** *ж.* — 1. ...белән ныгытылган яр; *гранитная набережная Невы* — Неваның гранит белән ныгытылган яры; 2. яр буе урамы; *Университетская набережная* — Университет янындагы яр буе урамы.

**НА'БЕРЕ'ЖЬЕ** *ср. обл.* — су буе, яр буе.

**НАБЕСЕ'ДОВАТЬСЯ** *сов. разг. фам.* — туйганчы сөйләшү.

**НАБИВА'ЛЬЩИК** *м. спец.* — набивальщик, тутыручы (снаряд, папирослар һ. б. төеп тутыручы эшче).

**НАБИВА'ТЬ** *несов.* — к. набить.

**НАБИВА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. набиться; 2. *страд.* тутырылу, төеп тутырылу; сугылу, бизәкләнү, бизәк төшерелү; күп итеп кагылу; ватылу.

**НАБИ'ВКА** *ж. мн.* нет, *спец.* — 1. (*действие*) к. набить; 2. эченә тутырылган нәрсә (мәсәлән, мамык, мунчала һ. б.); *из матраца торчит набивка* — матрацның эченә тутырылган нәрсәсе (мәсәлән, мамыгы) чыгып тора (күренеп тора).

**НАБИВНО'Й** *спец.* — 1. тутырып ясалган, тутырып ясала торган; *набивной тюфяк* — тутырып ясалган тюфәк; 2. бизәкле, бизәк төшерелгән, бизәк басылган; *набивной ситец* — бизәк төшерелгән ситсы; 3. сугыла торган, сугып киертелә торган; *набивной обруч* — сугып киертелә торган коршау.

**НАБИРА'ТЬ** *несов.* — к. набрать.

**НАБИРА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. набраться; 2. *страд.* җыелу, җыеп алыну; алыну, күп итеп алыну.

**НАБИ'ТЬ** *сов.* — 1. тутыру, төеп тутыру; *набить подушку пухом* — мендәргә мамык тутыру; *набить трубку* — трубкага тәмәке төеп тутыру; 2. сугу; *набить обруч на бочку* — мичкәгә коршау сугу; 3. *текст.* бизәкләү, бизәк төшерү, бизәк басу; *набить ситец* — ситсыга бизәк төшерү; 4. *простореч.* бәреп шештерү, кабартып чыгару; *набить шишку на лбу* — маңгаены бәреп шештерү, маңгайны кабартып чыгару; 5. *разг.* (күп итеп) кагу; *набить гвоздей в стену* — стенага күп итеп кадак кагу; 6. җиңү, өстен чыгу; *московские*

*футболисты набили приезжей команде* — Москва футболистлары читтән килгән команданы җиңделәр; 7. *разг.* вату; *сколько посуды набито!* — күпме (никадәр) савыт-саба ватылган! 8. *разг.* ату, атып төшерү (берникадәр); *сегодня охотник набил много уток* — бүген аучы (бик) күп үрдәк аткан. ◇ **Набить оскомину** — 1. теш камашу; 2. *перен.* теңкәгә тию. **Набить руку** — өйрәнеп җитү, остарып җитү. **Набить цену** — бәя күтәрү, хак күтәрү. **Набить карман (мошну)** *простореч.* — кесә калынайту, баю. **Набить морду** — авыз җимерү. **Набить холку** — атка камыт тидерү, атка камыт суктыру.

**НАБИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. *(скопиться во множестве)* тулу, шыгрым тулу; 2. *перен. фам.* тагылу, көчләп тагылу; *набиться в гости* — кунакка барам дип тагылу.

**НАБЛЕВА'ТЬ** *сов. просторечн. вульг.* — косып тутыру, косып пычрату, косып пычратып бетерү.

**НАБЛЁВЫВАТЬ** *несов.* — к. наблевать.

**НАБЛУДИ'ТЬ** *сов. просторечн.* — 1. *вульг.* бик күп уйнашлык итү; 2. *фам. (нашалить)* шаянлыклар эшләп ташлау.

**НАБЛЮДА'ТЕЛЬ** *м.* — күзәтүче; карап торучы, тикшереп торучы.

**НАБЛЮДА'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет — күзәтүчәнлек, дикъкатьлелек.

**НАБЛЮДА'ТЕЛЬНЫЙ** — 1. күзәтүчән, дикъкатьле; *наблюдательный человек* — күзәтүчән кеше; 2. күзәтү...-ы; *наблюдательный пункт* — күзәтү пункты.

**НАБЛЮДА'ТЕЛЬСКИЙ** *неодобр.* — күзәтүчеләрчә..., читтән карап торучыларча...; *наблюдательское отношение к делу* — эшкә күзәтүчеләрчә мөнәсәбәт (эш өчен җаны көймәү).

**НАБЛЮДА'ТЬ** *несов.* — 1. күзәтү, күзәтеп тору; *я с интересом наблюдал, как играют дети* — балалар уйнавын кызыксынып күзәтеп тордым; *наблюдать затмение солнца* — кояш тотылуны күзәтү; *милиционер наблюдает за уличным движением* — милиционер урамдагы хәрәкәтне күзәтеп тора; 2. *(выслеживать)* сиздермичә күзәтеп тору, яшертен күзәтеп тору; 3. карау, күз-колак булу, күзәтү; *наблюдать за ребёнком* — балага күз-колак булу. ◇ **В своей одежде он всегда наблюдал самую последнюю моду** — ул һәрвакыт соңгы мода буенча киенә иде.

**НАБЛЮДА'ТЬСЯ** *несов. книж.* — 1. *страд.* күзәтелү; *небесные тела наблюдаются в телескоп* — күктәге җисемнәр телескоп аша күзәтелә; 2. *(встречаться)* булгалау, очрау; 3. *(становиться заметным)* сизелү, беленү.

**НАБЛЮДЕ'НИЕ** *ср. книж.* — күзәтү.

**НАБО'Б** *м.* — набаб (1. Һиндстанда мөселман аристократларының титулы; 2. Һиндстанда эшләрен оста йөртә белүче хәйләкәр бай кеше).

**НА'БОЖНОСТЬ** *ж. мн.* нет — тәкъвалык.

**НА'БОЖНЫЙ** *рел.* — диндар, тәкъва.

**НАБО'ЙКА** *ж. спец.* — 1. *только ед.* к. набивка 1; 2. *(узорчатая ткань)* бизәкле тукыма, бизәк төшерелгән тукыма; 3. *(узор на ткани)* бизәк; 4. *сапож.* набойка (аяк киеме үкчәсенә сугыла торган күн яки резин кисәге).

**НАБО'ЙКОВЫЙ** *спец.* — к. набойчатый.

**НАБО'ЙЧАТЫЙ** *спец.* — бизәкле тукымадан тегелгән, бизәк төшерелгән тукымадан тегелгән; *набойчатое платье* — бизәкле тукымадан тегелгән күлмәк.

**НАБО'ЙЩИК** *м. спец.* — 1. набойщик, тутыручы, төеп тутыручы; *набойщик в табачном производстве* — тәмәке производствосында набойщик (тутыручы); 2. *текст.* набойщик (тукымаларга бизәк төшерүче).

**НА'БОК** *нареч.* — бер якка, янга, кырын.

**НАБОЛЕ'ВШИЙ** — 1. авырткан, авырта торган, сызлаган; 2. *перен.* борчулы, борчый торган, әһәмият бирүне таләп итә торган, күптән вакыты җиткән; *наболевший вопрос* — борчый торган мәсьәлә, күптән вакыты җиткән мәсьәлә.

**НАБОЛЕ'ТЬ** *сов.* — авырту, сызлау. ◇ **Наболело на душе** *перен. безл.* — күңелем кайгы-хәсрәт белән тулды; чыдар хәл калмады; эчем яна. **Выложить всё, что наболело на душе** — эч янганын бушату, йөрәк янганын бушату (эчкә җыелган барлык кайгыларны сөйләп бирү).

**НАБОЛТА'ТЬ** I *сов. разг.* — тугылап кушу, болгатып кушу; *наболтать яиц в молоко* — сөткә йомырка тугылап кушу.

**НАБОЛТА'ТЬ** II *сов. просторечн. фам.* — 1. күп лыгырдау, такылдау, сөйләп ташлау, сөйләп бетерү; *бог знает, что наболтал* — ниләр такылдаганын алла белсен (әллә ниләр сөйләп бетерде мәгънәсендә); *просидел целый час, наболтал всякой чепухи* — бер сәгать буе җыен юк-барны лыгырдап утырды; 2. *(наклеветать)* яла ягу.

**НАБОЛТА'ТЬСЯ** *сов. просторечн. фам.* — туйганчы лыгырдау, туйганчы ләчтит сату.

**НА'БОЛЬШИЙ** *обл.* — башлык, җитәкче, начальник; *их набольший жил в губернаторском доме* — аларның башлыгы губернатор йортында тора иде.

**НАБО'Р** *м.* — 1. *только ед.* к. набрать; *отдать рукопись в набор* — кульъязманы җыярга бирү (наборга бирү); *набор учащихся в ремесленные училища* — һөнәр мәктәпләренә укучылар алу; 2. җыелма; *набор красок* — буяулар җыелмасы; 3. *тип.* набор; *рассыпать набор* — наборны чәчеп җибәрү. ◇ **Набор слов** *неодобр.* — мәгънәсез сүзләр җыелмасы. **Упряжь с набором** — җизле (җиз таккан) сбруй.

**НАБОРМОТА'ТЬ** *сов. просторечн.* — мыгырдау, мыгырдап сөйләп ташлау.

**НАБО'РНАЯ** *в знач. сущ.* — типографиядә хәреф җыю бүлеге.

**НАБО'РНЫЙ** *тип.* — 1. набор...-ы; хәреф җыю...-ы; *наборное дело* — набор эше; *наборная машина* — хәреф җыю машинасы; 2. җизле, бизәкле; *наборная сбруя* — җизле (җиз таккан) сбруй.

**НАБО'РТНЫЙ** *спец.* — 1. *(на борту суд-*

*на)* борттагы; 2. *(на борту платья)* каплавмадагы.

**НАБО'РЩИК** *м. тип.*— наборщик, хәреф җыючы.

**НАБРАКОВА'ТЬ** *сов. разг.*— бик күбесен яраксыз итеп табу, күп итеп яраксызга чыгарту, бик күп бракка чыгару.

**НАБРАКО'ВЫВАТЬ** *несов. разг.*—к. набраковать.

**НАБРА'СЫВАТЬ** *несов.*— к. набросить, набросать.

**НАБРА'СЫВАТЬСЯ** *несов.*—1. к. наброситься; 2. *страд.* ыргытылу, күп итеп ташлану.

**НАБРА'ТЬ** *сов.* — 1. (берникадәр, әллә никадәр) җыю, җыеп алу; *набрать стакан ягод* — бер стакан җиләк җыю; *набрать книг в магазине* — магазиннан әллә никадәр китап алу; 2. *тип.* җыю; *набрать книгу* — китап җыю; 3. (берникадәр) алу; *паровоз набрал воды и угля* — паровоз су һәм күмер алды; 4. *разг.* күп итеп алу, күп итеп җыю; *набрал уроков, а потом не знал, как справиться* — дәрес сәгатьләрен күп итеп алган да, аннан соң ничек башкарып чыгарга белмәде; 4. кирәкле дәрәҗәгә җиткерү; *паровоз набрал скорость* — паровоз йөреш тизлеген кирәкле дәрәҗәгә җиткерде. ◇ **Набрать на стол** *обл.*— табын хәзерләү. **Набрать высоту** *авиац.*— югары күтәрелү, тиешле биеклеккә менү.

**НАБРА'ТЬСЯ** *сов.*—1. *чаще безл.* (берникадәр) кереп тулу, җыелу; *в трамвае набралось много народу* — трамвайга бик күп халык кереп тулды; *желающих набралось до десятка* — теләүчеләр унга якын җыелды; 2. *разг.* (берникадәр) булу, тулу; *тридцати вёрст не будет, а коли... кони наморены, то целых пятьдесят наберётся* (Чехов) — утыз чакрым да булмас, ә инде атлар арыган булса, иллегә дә тулар; 3. *разг.* өйрәнү, башка тутыру; *крепко набрался каких-то новых правил* — башына ниндидер яңа кагыйдәләр дыңгычлап тутырган. ◇ **С кем поведёшься, от того и наберёшься** — кем чанасына утырсаң, шуның җырын җырларсың. **Набраться храбрости** (или **смелости**)—батырлык итү, кыюлык итү, батырлык җитү, кыюлык җитү. **Набраться сил** — көч җыю.

**НАБРЕДА'ТЬ** *несов.*— к. набрести.

**НАБРЕСТИ'** *сов. разг.*—1. очрату, күрү, юлыгу; *нечаянно набрёл на знакомых в толпе* — көтмәгәндә халык арасында танышларны очраттым (танышларыма юлыктым); 2. килеп чыгу, барып чыгу; *я набрёл на тропинку* — мин сукмакка килеп чыктым; 3. акрын-акрын җыелу, акрынлап җыелу; *набрело много народу* — акрынлап күп халык җыелды. ◇ **Набрести на мысль** — фикергә килү. **Набрести на открытие** — ачыш ясау. **Набрести на след**— эзенә төшү.

**НАБРЕХА'ТЬ** *сов. простореч.*—1. *(о собаке)* өрү; 2. *вульг. перен.* бик күп юк-бар нәрсә сөйләп ташлау, ялганлау; 3. *вульг.* яла ягу.

**НАБРОДИ'ТЬСЯ** *сов. разг. фам.*— туйганчы йөрү, арыганчы йөрү.

**НАБРОНЗИРОВА'ТЬ** *сов. спец.*— бронзалау, бронза йөгертү.

**НАБРОНЗИРО'ВЫВАТЬ** *несов. спец.*— к. набронзировать.

**НАБРОСА'ТЬ** *сов.*—1. (күп итеп) ташлау, ыргыту; *набросать камней* — күп итеп таш ыргыту; 2. өстән-өстән генә сызып чыгу, өстән-өстән генә язып чыгу; өстән-өстән генә язып ташлау, тиз-тиз генә язып ташлау; *я набросал несколько мыслей на бумаге* — кәгазьгә тиз-тиз генә берничә фикер язып ташладым; 3. сурәтләп бирү; *оратор набросал яркую картину будущего* — оратор киләчәкнең гүзәл күренешен сурәтләп бирде.

**НАБРО'СИТЬ** *сов.*—салу, ябу; *набросить платок на плечи* — җилкәгә (иңгә) шәл салу. ◇ **Набросить тень** — йөзгә кара ягу, тап төшерү.

**НАБРО'СИТЬСЯ** *сов. разг.*—1. ыргылу, ташлану; *собака набросилась на незнакомца* — эт ят кеше өстенә ташланды; 2. ябырылу, йотлыгып...-а башлау; комсызланып...-а башлау; *наброситься на еду* — комсызланып ашый башлау; *наброситься на новую книгу* — яңа китапны йотлыгып укый башлау. ◇ **Наброситься с упрёками** — кинәт шелтәли башлау. **Наброситься с вопросами** — сораулар яудыра башлау.

**НАБРО'СОК** *м.*— каралама, набросок (әсәрнең, речьнең канвасы, проекты; өстән-өстән генә ясалган рәсем).

**НАБРЫ'ЗГАТЬ** *сов. разг.*— чәчрәтү, чәчрәтеп пычрату, пычратып бетерү; *маляр набрызгал на пол краской* — маляр идәнне буяу белән пычратып бетергән.

**НАБРЮЗЖА'ТЬ** *сов. разг.*— мыгырдау, мыгырдап алу, күп мыгырдау.

**НАБРЮ'ШНИК** *м.*— түшлек.

**НАБРЮ'ШНЫЙ** — корсак...-ы; корсак өсте...-ы; *набрюшный жировой слой* — корсак өсте май катламы.

**НАБУРА'ВИТЬ** *сов. спец.*— бораулау, бораулау белән тишү.

**НАБУТИ'ТЬ** *сов. спец.*— бут җәю, бут җәеп чыгу (мәсәлән, урамга).

**НАБУ'ХАТЬ** *сов. простореч. шутл.*— (күп итеп) салу, күп тутыру, гадәттән тыш күп салу.

**НАБУХА'ТЬ** *несов.*— к. набухнуть.

**НАБУ'ХНУТЬ** *сов.*—1. бүртү; күбү; *на деревьях набухли почки* — агачларның бөреләре бүрткән; 2. шешү, шешенү; *веки набухли от слёз* — елаудан күз кабаклары шешенгән.

**НАБУ'ЧИВАТЬ** I *несов. спец.*— к. набутить.

**НАБУ'ЧИВАТЬ** II *несов. спец.*— к. набучить.

**НАБУ'ЧИТЬ** *сов. спец.*— керне селтедә чылату, керне селтедә чылатып кую.

**НАБУШЕВА'ТЬ** *сов. разг. фам.*— туйганчы дулау, туйганчы тавышлану.

**НАБУЯ'НИТЬ** *сов. разг.*— гауга куптарып, әллә нинди эшләп ташлау.

**НАВА'ГА** *ж. зоол.*— навага (балык).

**НАВАЖДЕ'НИЕ** *ср. устар.*— к. навождение.

**НАВА'ЖИЙ** — навага...-ы; *наважий суп*— навага шулпасы.

**НАВА'КСИТЬ** *несов.*— к. ваксить.

**НАВА'ЛИВАТЬ** I *несов.*— к. навалить.

**НАВА'ЛИВАТЬ** II *несов. разг.*— к. навалять 1.

**НАВА'ЛИВАТЬСЯ** *несов.* —1. к. навалиться; 2. *страд.* куелу, салыну, аударылу.

**НАВАЛИ'ТЬ** *сов.*—1. кую, салу; *навалить один мешок на другой* — бер капчыкны икенчесе өстенә салу (кую); 2. *перен. разг. фам.* йөкләү; *навалили на меня кучу забот* — минем өскә бик күп мәшәкатьләр йөкләделәр; 3. *разг.* (күп итеп) аудару; *навалить картошки* — күп итеп бәрәңге аудару; 4. салу; *навалить мешок на спину* — капчыкны аркага салу; 5. *простореч.* күп җыелу; *изо всех деревень народу навалило* — барлык авыллардан бик күп халык җыелды. ◇ **Навалило много снегу** — бик күп кар яуган.

**НАВАЛИ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. *(налечь)* яту, басу, таяну; 2. *(внезапно напасть)* көтмәгәндә һөҗүм итү, көтмәгәндә ташлану, ябырылу; 3. *разг. фам.* йотлыгып ...-а башлау, комсызланып ...-а башлау; *навалился он на кашу* — ботканы ул комсызланып ашый башлады; 4. *разг.* коелу, күп итеп коелу; *навалилось много листьев в пруд* — буага бик күп яфрак коелган.

**НАВА'ЛОМ** *нареч.*— (капчыкка яки башка нәрсәгә салмыйча гына) түәп, болай гына салып.

**НАВАЛЯ'ТЬ** *сов.*—1. *разг.* аудару, күп итеп аудару; *сколько лесу наваляли!* — никадәр агач аударганнар! 2. (берникадәр) басу; *навалять валенок* — (берникадәр) киез итек басу; 3. *простореч.* ничек җитте алай эшләп ташлау.

**НАВАЛЯ'ТЬСЯ** *сов. разг. фам.*— туйганчы яту, туйганчы ятып тору; туйганчы аунау; бик озак яту, озак ятып тору.

**НАВА'Р** *м.*— өре, чыр, шулпа өсте.

**НАВА'РИВАТЬ** *несов.*— к. наварить.

**НАВА'РИВАТЬСЯ** *несов. страд.*—1. пешерелү, күп итеп пешерелү; 2. *тех.* кыздырып ябыштырылу (металл турында).

**НАВА'РИСТЫЙ** — өреле, чырлы.

**НАВАРИ'ТЬ** *сов.*—1. (күп итеп) пешерү; *наварить каши* — күп итеп ботка пешерү; 2. *тех.* *(приварить)* кыздырып ябыштыру, кыздырып ялгау (металлны).

**НАВАРНО'Й** *тех.*— кыздырып ябыштырылган; кыздырып ялганган; *наварная ось* — кыздырып ябыштырылган күчәр.

**НАВА'РНЫЙ** *разг.*— к. наваристый.

**НАВА'СТРИВАТЬ** *несов. простореч.*— к. навострить.

**НАВА'СТРИВАТЬСЯ** *несов. простореч.*— к. навостриться.

**НАВА'ЩИВАТЬ** *несов. спец.*— к. навощить.

**НАВА'ЩИВАТЬСЯ** *несов. страд. спец.*— балавызлану, балавыз белән ялтыратылу.

**НАВЕВА'ТЬ** *несов.*— к. навеять.

**НАВЕ'ДАТЬСЯ** *сов. разг.*— хәл белергә кереп чыгу, кереп чыгу; *наведайтесь к нам как-нибудь* — ничек тә (булса) безгә кереп чыгыгыз.

**НАВЕ'ДЫВАТЬСЯ** *несов. разг.*— к. наведаться.

**НАВЕЗТИ'** *сов. разг.*—1. (күп итеп) китерү, китереп кую, китереп тутыру; ташып кую; *навезти товаров* — (күп итеп) товарлар китерү; 2. *простореч.* бәрдерү; *вези, да на камень не навези* — илт, ләкин ташка бәрдермә.

**НАВЕ'ИВАТЬ** *несов. с.-х.*— к. навеять 2.

**НАВЕ'ИВАТЬСЯ** *несов. страд. с.-х.*— (берникадәр) җилгәрелү, суырылу.

**НАВЕ'К, НАВЕ'КИ** — гомергә, мәңгегә, бөтенләйгә.

**НАВЕРБОВА'ТЬ** *сов.*— вербовать итү, вербовать итеп алу.

**НАВЕРБО'ВЫВАТЬСЯ** *несов. страд.*— вербовать ителү, вербовать итеп алыну.

**НАВЕ'РНО** — 1. *ввод. сл.* мөгаен, ...-дыр, ...булса кирәк, ...дип уйларга кирәк; *наверно, так и будет* — мөгаен, шулай булыр да; 2. *в знач. сказ.* һичшиксез (булачак), әлбәттә (булачак), чынлап та (булачак); *будь покоен, это уж наверно* — тыныч бул, бу инде һичшиксез (булачак).

**НАВЕ'РНОЕ** —1. *ввод. сл.* к. наверно 1; 2. *нареч. устар.* к. наверняка.

**НАВЕРНУ'ТЬ** *сов.*—1. чорнау, урау, чорнап кую, урап кую; *навернуть холст на вал* — киндерне валга урап кую; 2. борып кертү; *навернуть гайку на ось* — гайканы күчәргә борып кертү; 3. *простореч.* бүсү, сугу (бик күп ашау мәгънәсендә); *навернул много хлеба* — бүстем дә соң ипине (бик күп ипи ашадым).

**НАВЕРНУ'ТЬСЯ** *сов.*—1. *(обмотаться вокруг чего-н.)* чорналу, уралу; 2. *простореч.* очрау, туры килү; *навернулась интересная тема* — кызыклы бер тема туры килде. ◇ **На глаза навернулись слёзы** — күзләренә яшь тулды.

**НАВЕРНЯКА'** *нареч. разг.*—1. һичшиксез, әлбәттә, тәгаен; *он наверняка придёт* — ул һичшиксез килер; 2. нык ышанып, тулы ышаныч белән, яхшы белеп, ялгышмыйча; *действовать наверняка* — нык ышанып эш итү.

**НАВЕРСТА'ТЬ** I *сов.*— тутыру, каплау, эшләп бетерү; *наверстать упущенное* — эшләнми калган эшне (эшләп) бетерү.

**НАВЕРСТА'ТЬ** II *сов. тип.*— (берникадәр) верстать итү, вёрсткалау, биткә салу.

**НАВЁРСТЫВАТЬ** I *несов.*— к. наверстать I.

**НАВЁРСТЫВАТЬ** II *несов. тип.*— к. наверстать II.

**НАВЁРСТЫВАТЬСЯ** I *несов. страд.*— тутырылу, каплану, бетерелү.

**НАВЁРСТЫВАТЬСЯ** II *несов. страд. тип.*—(берникадәр) верстать ителү, верстка- лану, биткә салыну.

**НАВЕРТЕ'ТЬ** *сов.*—1. *(намотать)* чорнау, урау, чорнап кую, урап кую; 2. бораулап тишү; бораулап тишеп чыгу; *навертеть дыр* — бораулап тишекләр тишеп чыгу.

**НАВЁРТКА** *ж. спец.*—1. *только ед. (действие)* к. навертеть; 2. навёртка, кечкенә борау.

**НАВЁРТЫВАТЬ** *несов.* — к. навернуть.

**НАВЁРТЫВАТЬСЯ** *несов.*—1. к. навернуться; 2. *страд.* чорналу, уралу, чорнап куелу, урап куелу; борып кертелү.

**НАВЕ'РХ** *нареч.*—1. югарыга, өскә, өске катка; *переселили из подвалов наверх* — подваллардан өске катка (югарыга) күчерделәр; 2. югарыга, өскә, югарыга таба, өскә таба; *взглянуть наверх* — өскә (өскә таба) карау.

**НАВЕРХУ'** *нареч.*— югарыда, өстә, өске каттa; *он живёт наверху* — ул өске катта тора.

**НАВЕ'РЧИВАТЬ** *несов.*— к. навертеть 2.

**НАВЕ'РЧИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— боpаулап тишелү.

**НАВЕ'С** *м.*—1. түбә, төз лапас, әвеслек; *навес над колодцем* — кое түбәсе; *навес над крыльцом* — болдыр түбәсе; 2. чыгынты (берәр нәрсәнең чыгып тора торган өлеше); *навес скалы* — кыя чыгынтысы.

**НАВЕСЕЛЕ'** *нареч. разг.*— кәефле, кызмача (аз гына исерек).

**НАВЕ'СИСТЫЙ** *обл.*— чыгынкы, чыгынтылы, чыгып тора торган; *навесистая крыша* — чыгынкы түбә; *навесистый берег* — чыгынтылы яр. ◇ **Навесистый дуб** — кин ябалдашлы имән.

**НАВЕ'СИТЬ** *сов.*—1. *разг.* к. навешать 1; 2. кую, утырту; *навесить дверь* —ишек кую; 3. элү, асу; *навесить тушу на крюк* — ит түшкәсен ыргакка элеп (асып) кую.

**НАВЕ'СКА** *ж. спец.*—1. *только ед. (действие)* к. навесить 1; 2. (*петля*) күгән.

**НАВЕСНО'Й** *просторец. спец.*— к. навесный 3.

**НАВЕ'СНЫЙ** —1. лапас...-ы; *навесный столб* — лапас баганасы; 2. чыгынкы; *навесное положение* — чыгынкы торыш; 3. *спец.* күгәнле, асылмалы; *навесная дверь* — асылмалы ишек.

**НАВЕСТИ'** *сов.*—1. китереп чыгару; *навести отряд на деревню* — отрядны авыл янына китереп чыгару; 2. *перен.* китерү, тудыру, бирү, төшерү, калдыру; *навести на мысль* — фикер тудыру; *навести на идею* — идея бирү; *навести на размышление* — уйга төшерү (калдыру); 3. *перен.* юнәлтү, күчерү, бору; *навести разговор на тему о...* — сүзне ... турындагы темага күчерү; 4. *разг.* кертеп тутыру, китереп тутыру; *навести гостей в дом* — өйгә кунаклар китереп тутыру; 5. юнәлтү, турылау, төзәү, төбәү; *навести телескоп на луну* — телескопны айга таба турылау; *навести револьвер* — револьвер төзәү (төбәү); 6. йөгертү; *навести зеркало серебром* — көзгегә көмеш йөгертү. ◇ **Навести глянец** *(или блеск)* — ялтырату. **Навести узоры** *(на что-н.)*—(берәр нәрсәгә) бизәк төшерү. **Навести красоту** — матурлау. **Навести порядок** — тәртипкә салу, тәртип кертү, тәртип урнаштыру. **Навести страх**—куркыту, курку салу, котын очыру, котын алу. **Навести тоску** — эч пошыру, пошындыру. **Навести мост** — күпер салу. **Навести тень** — йөзгә кара ягу, тап төшерү. **Навести справку** — белешү. **Навести критику** *просторец.*— тәнкыйтьләү. **Навести на путь истинный** *разг.*— туры юлга салу, дөрес юлга бастыру.

**НАВЕСТИ'ТЬ** *сов.* — хәл белү, хәл белергә бару, хәл белергә кереп чыгу, кереп чыгу.

**НАВЕСУ'** *нареч.*— асылынып, асылынган хәлдә; *держаться навесу* — асылынып тору.

**НАВЕ'Т** *м. книж. устар.*— яла.

**НАВЕ'ТРЕННЫЙ** *спец.*— *наветренная сторона* — җил искән як, җилгә каршы як; *наветренный корабль* — җил уңаена бара торган корабль.

**НАВЕ'ТЧИК** *м.*, **НАВЕ'ТЧИЦА** *ж. книж. устар.*— яла ягучы, ялачы.

**НАВЕ'ЧНО** *нареч.*— мәңгегә, гомергә.

**НАВЕ'ШАТЬ** *сов.*— 1. күп итеп тагып кую, күп итеп элеп кую; *навешать картин на стену* — стенага күп итеп рәсемнәр элеп кую; *навешать белья* — күп итеп кер элеп кую; 2. *разг.* алдан күп итеп үлчәп-үлчәп кую; *навешать конфет* — алдан күп итеп конфет үлчәп-үлчәп кую.

**НАВЕ'ШИВАТЬ** I *несов.*— к. навесить.

**НАВЕ'ШИВАТЬ** II *несов.*— к. навешать.

**НАВЕ'ШИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— (күп итеп) тагып куелу, (күп итеп) элеп куелу; күп итеп алдан үлчәп-үлчәп куелу.

**НАВЕЩА'ТЬ** *несов.*— хәл белә тору, хәл белергә килү, хәл белергә бару.

**НАВЕ'ЯТЬ** *сов.*— 1. китерү; өреп китерү, өреп алып килү; *ветер навеял прохладу* — җил исеп, салкынча һава китерде; 2. *с.-х.* җилгәреп кую, суырып кую. ◇ **Навеять тоску** — эч пошыру.

**НА'ВЗНИЧЬ** *нареч.* — чалкан; *упасть навзничь* — чалкан егылу.

**НАВЗРЫ'Д** *нареч.*: **плакать навзрыд** — акырып елау, үксеп-үксеп елау, үкси-үкси елау.

**НАВИВА'ТЬ** *несов.*— к. навить.

**НАВИВА'ТЬСЯ** *несов.*—1. к. навиться; 2. *страд.* чорналу, уралу, чорнап куелу, урап куелу.

**НАВИГА'ТОР** *м. мор.*— навигатор (суднода хезмәт итүче; судно узган юлның озынлыгын һәм судноның торган урынын билгеләүче).

**НАВИГАЦИО'ННЫЙ** *мор.* — навигация ...-ы; *навигационный сезон* — навигация сезоны.

**НАВИГА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет —1. навигация (а. *мор.* корабльләр, пароходлар йөртү фәне һәм сәнгате; б. корабльләр, пароходлар йөрү вакыты, сезоны; в. к. аэронавигация); 2. *мор.* навигация, пароходлар йөреше, корабльләр йөреше.

**НАВИДА'ТЬСЯ** *сов. разг.*— күпне күрү; туйганчы карап тору, туйганчы карау.

**НАВИЗЖА'ТЬСЯ** *сов. разг.*— туйганчы чинау, туйганчы чыелдау, чинап тую, чыелдап тую.

**НАВИНТИ'ТЬ** *сов.*— борып кертү.

**НАВИ'НЧИВАТЬ** *несов.*— к. навинтить.

**НАВИ'НЧИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— борып кертелү.

**НА'ВИС** *м. спец.*— атның ялы һәм койрыгы.

**НАВИСА'ТЬ** *несов.*— салынып тору; *брови нависают на глаза* — кашлары күзенә салынып тора. ◇ **Скалы нависают над морем** — кыялар диңгез өстенә чыгып торалар. **Тучи нависают над долиной** — болытлар үзәнне каплап алганнар. **Над нами нависает угроза** — без куркыныч алдында торабыз.

**НАВИ'СЛЫЙ** *разг.*— салынкы, салынып тора торган; *навислые брови* — салынкы кашлар.

**НАВИ'СНУТЬ** *сов.*— салынып төшү.

**НАВИ'СШИЙ** — салынкы, салынып тора торган.

**НАВИ'ТЬ** *сов.*—1. *(намотать)* чорнау, урау, чорнап кую, урап кую; 2. (күп итеп) ишеп кую, (күп итеп) үреп кую; *навить верёвок* — (күп итеп) бау ишеп кую; 3. *обл.* сәнәк белән төяү; *навить солому на воз*— йөккә сәнәк белән салам төяү.

**НАВИ'ТЬСЯ** *сов.*— чорналу, уралу.

**НАВЛЕКА'ТЬ** *несов. книж.*— к. навлечь.

**НАВЛЕ'ЧЬ** *сов. книж.*— тудыру, чыгару; китереп чыгару; *навлечь беду* — бәла тудыру, бәла китереп чыгару.

**НАВОДИ'ТЬ** *несов.*— к. навести.

**НАВОДИ'ТЬСЯ** *несов. страд.*—1. китереп чыгарылу; 2. китерелү, тудырылу, бирелү, төшерелү, калдырылу; 3. юнәлдерелү; 4. йөгертелү.

**НАВО'ДКА** *ж.*— 1. *(об орудиях)* төзәү, төбәү, наводка; 2. *(о приборах)* юнәлтү, турылау; 3. *(о глянце)* ялтырату; 4. *(о мосте)* салу; 5. *(о зеркале)* йөгертү.

**НАВОДНЕ'НИЕ** *ср.*—1. су басу, ташкын; *помощь пострадавшим от наводнения* — су басудан зарар күргәннәргә ярдәм итү; 2. *только ед. (действие)* к. наводнить.

**НАВОДНИ'ТЬ** *сов.*—1. *редко* су басу; 2. *перен. преимущ. неодобр.* тутыру, китереп тутыру; *наводнили рынок дешёвыми товарами* — базарга арзанлы товарлар китереп тутырганнар.

**НАВОДНИ'ТЬСЯ** *сов.*—1. *редко* су астында калу; 2. *перен. преимущ. неодобр.* тулу.

**НАВОДНО'Й** *устар.*, **НАВО'ДНЫЙ** *спец.*— 1. сүтелмәле, сүтеп алынмалы, вакытлыча салына торган; *наводной мост* — сүтелмәле күпер; 2. йөгертелгән; *наводной лоск*— йөгертелгән ялтыравык.

**НАВОДНЯ'ЕМОСТЬ** *ж. мн.* нет, *спец.*— су басу, су астында калу(чанлык).

**НАВОДНЯ'ТЬ** *несов.*— к. наводнить.

**НАВОДНЯ'ТЬСЯ** *несов.*— к. наводниться.

**НАВО'ДЧИК** *м.*—1. *воен.* наводчик, төзәүче, төбәүче, коралны төзәүче, төзәп торучы хәрби хезмәткәр; 2. көмеш йөгертүче, буяучы, ялтыратучы; *наводчик зеркал* — көзгеләргә көмеш йөгертүче.

**НАВОДЯ'ЩИЙ ВОПРО'С** — юнәлдергеч сорау, ярдәмче сорау.

**НАВОЕВА'ТЬ** *сов. устар.*— (берникадәр нәрсә) сугышып алу.

**НАВОЕВА'ТЬСЯ** *сов. разг.*—1. *устар.* туйганчы сугышу, сугышып тую; 2. *перен. шутл.* кычкырышып тую, гауғалашып тую, туйганчы кычкырышу.

**НАВОЖДЕ'НИЕ** *ср.*—1. вәсвәсә; 2. *разг. шутл.* искиткеч нәрсә, гаҗәп бер күренеш, аңлашылмаслык эш.

**НАВО'З** *м. мн.* нет — 1. тирес; 2. *перен. разг. пренебр. бран.* чүп-чар, яраксыз әйберләр.

**НАВО'ЗИТЬ** *несов.*—1. *с.-х.* тиресләү, тирес белән ашлау, тирес кертү; 2. *простореч. неодобр.* пычрату.

**НАВОЗИ'ТЬ I** *несов.*— к. навезти.

**НАВОЗИ'ТЬ II** *сов. разг.*— (берникадәр) ташу, ташып кую, ташып хәзерләп кую; *навозить дров на целую зиму* — кышлык утын ташып (хәзерләп) кую.

**НАВО'ЗИТЬСЯ** *несов.*—1. *страд. с.-х.* тиресләнү, тирес белән ашлану, тирес кертелү; 2. *простореч. неодобр.* пычрану.

**НАВОЗИ'ТЬСЯ I** *несов. страд.*— (берникадәр) китерелү, ташып куелу, китереп куелу, ташып хәзерләп куелу.

**НАВОЗИ'ТЬСЯ II** *сов. разг.*— туйганчы шаяру, туйганчы уйнау.

**НАВО'ЗНИК** *м.*—1. *зоол.* тирес коңгызы; 2. *спец.* тирес хәзерләүче, тирес ташучы, тирес түгүче; 3. *спец.* тирес ящигы.

**НАВО'ЗНИЦА** *ж. с.-х.*—кырларга тирес чыгару вакыты.

**НАВО'ЗНЫЙ** — тирес...-ы; *навозный запах* — тирес исе; *навозный жук* — тирес коңгызы.

**НАВО'Й** *м.*—1. *спец.* навой, күшә (туку станогында буй җепне чорнау валы); 2. *только ед.* к. навить.

**НАВОЛА'КИВАТЬ** *несов. разг.*— к. наволочь.

**НА'ВОЛОК** *м. обл.*— су баса торган болын, су астында кала торган болын; елганың инсү яры.

**НА'ВОЛОКА** *ж. разг.*, **НА'ВОЛОЧКА** — мендәр тышы.

**НАВОЛО'ЧЬ** *сов. разг.*— китереп тутыру; китереп өю, ташып кую; *наволок сюда всякой дряни* — әллә нинди чүп-чар китереп өйгән шунда. ◇ **На небо туч наволокло** — күк йөзен болытлар каплап алды; күк болытланды.

**НАВОНЯ'ТЬ** *сов. разг. неодобр.*— сасыту.

**НАВОРА'ЖИВАТЬ** *несов. устар.*— к. наворожить.

**НАВОРА'ЧИВАТЬ** *несов. простореч. неодобр.*—к. наворотить.

**НАВОРА'ЧИВАТЬСЯ** *несов. страд. простореч. неодобр.*— тәртипсез өеп куелу, күп итеп өеп куелу, бик күп аударылу.

**НАВОРОВА'ТЬ** *сов. разг.*— урлап җыю, күп итеп урлау.

**НАВОРО'ВЫВАТЬ** *несов. разг.*— к. наворовать.

**НАВОРО'ВЫВАТЬСЯ** *несов. страд. разг.*— урлап җыелу, күп итеп урлану.

**НАВОРОЖИ'ТЬ** *сов. устар.*—1. *(ворожа, предсказать)* (күрәзәлек итеп) алдан әйтү, алдан әйтеп бирү; 2. *(нажить ворожбой)*

күрәзәлек итеп акча жыю, багучылык итеп акча жыю.

**НАВОРОТИ'ТЬ** *сов. простореч. неодобр.*— 1. тәртипсез өеп кую, күп итеп өеп кую, (күп итеп) аудару; *наворотить камней* — бик күп таш аудару; 2. *перен. фам.* ничек җитте алай эшләү (сөйләү, язу), тәртипсез эшләп (сөйләп, язып) ташлау.

**НАВОРОШИ'ТЬ** *сов.*—1. *(о сене)* кабартып чыгу; 2. *(о печи)* болгату, бутау.

**НАВОРЧА'ТЬ** *сов. разг. фам.*— мыгырданып әрләү, орышу.

**НАВОРЧА'ТЬСЯ** *сов. разг. фам.*— туйганчы мыгырданып әрләү, туйганчы мыгырданып орышу.

**НАВОСТРИ'ТЬ** *сов. простореч.*—үткенләү, кайрау. ◇ **Навострить уши**—*(о человеке)* игътибарны көчәйтү; *(о лошади)* колак торгызу, колак шәмрәйтү. **Навострить лыжи** — таярга җыену (китәргә хәзерләнеп кую, качарга хәзерләнеп кую).

**НАВОСТРИ'ТЬСЯ** *сов. простореч.*— өйрәнеп җиту, остарып җиту.

**НАВОЩИ'ТЬ** *сов.*— балавызлау, балавызлап ялтырату.

**НАВРА'ТЬ** *сов. простореч.*—1. (әллә ниләр) ялганлау, ялган сөйләү; 2. яла ягу; *наврал на соседа* — күршесенә яла яккан; 3. ялгышу, ялгыш эшләү, хата җибәрү, хата ясау; *наврать в переводе* — тәрҗемәдә хата җибәрү.

**НАВРА'ТЬСЯ** *сов. простореч.*— туйганчы ялганлау.

**НАВРЕДИ'ТЬ** *сов. разг.*— (күп) зарар китерү, (күп) зарар итү, корткычлык итү.

**НАВРЯ'Д** *нареч. устар. простореч.* и **НАВРЯ'Д ЛИ** *нареч. разг.*— ай-һай, ай-һай булырмы икән, белмим булырмы.

**НАВСЕГДА'** *нареч.*— гомергә, мәңгегә, бөтенләйгә.

**НАВСТРЕ'ЧУ** *нареч.* — каршы, карак-аршы, каршыга. ◇ **Идти навстречу** *перен.*—1. ...-га таба бару, ...-га бару; *идти навстречу гибели* — һәлакәткә таба бару; 2. булышлык итү, ярдәм итү, ярдәмле булу; *идти навстречу (кому-н.)*—(кемгә дә булса) ярдәм итү.

**НАВЫ'ВОРОТ** *нареч. простореч.*—1. *(наоборот)* киресенчә; 2. *(наизнанку)* тискәре ягы белән. ◇ **Шиворот-навыворот** — киресенчә.

**НАВЫ'ДУМАТЬ** *сов. простореч.*—уйлап чыгару; әллә нилəр уйлап чыгару, юкбарны уйлап чыгару.

**НАВЫДУ'МЫВАТЬ** *несов. простореч.*— к. навыдумать.

**НА'ВЫК** *м.*—1. нялэшү, өйрәнеп җиту, нялэшеп җиту, күнегү, күнегеп җиту, осталык; *у меня нет ещё навыка к этой работе* — мин әле бу эшкә күнегеп җитмәгән; 2. *педаг.* күнекмә; *школа должна давать твёрдые практические навыки читать, писать, считать и т. д.* — мәктәп уку, язу, санауда һ. б. ныклы практик күнекмәләр бирергә тиеш; 3. *псих. педаг.* гадәт; *ходьба, речь, трудовые движения относятся к числу навыков* — йөрү, сөйләү, эш хәрәкәтләре гадәтләрдән саналалар.

**НАВЫ'КАТ** и **НАВЫ'КАТЕ:** глаза навыкат (или навыкате)—күзләре акайган, акай күзләр.

**НАВЫКА'ТЬ** *несов. простореч.*— нялэшү, күнегү, гадәтләнү.

**НАВЫ'КНУТЬ** *сов. простореч.*—нялэшеп җиту, нялэшеп бетү, күнегеп җиту, күнегеп бетү, гадәтләнеп бетү, нялэшеп киту, гадәтләнеп киту.

**НАВЫ'ЛЕТ** *нареч.*— үтәли тишеп, үтә тишеп; *ранен пулей навылет* — пуля үтәли тишеп чыккан.

**НАВЫ'НОС** *нареч. разг.* — алып чыгу өчен (эчемлекләрне сатылган урынында эчмичә сатып алып чыгу өчен).

**НАВЫ'ПУСК** *нареч.*: брюки **навыпуск**— балакларын чыгарып (итек кунычлары эченә тыгылмыйча) киелгән чалбар; **рубаха навыпуск**—итәге чалбар эченә тыгылмыйча киелгән күлмәк.

**НАВЫ'РЕЗ** *нареч.*— кисеп карап, кистереп карап; *купить арбуз навырез* — кистереп карап карбыз сатып алу.

**НАВЫ'ТЯЖКУ:** **стоять навытяжку** — катып тору, туры басып тору, шәм кебек тору.

**НАВЬЮ'ЧИВАТЬ** *несов.*—(хайван аркасына) йөк салу, йөк төяү.

**НАВЬЮ'ЧИВАТЬСЯ** *несов.*—1. *разг. фам.* к. навьючиться; 2. *страд.* (хайван аркасына) йөк салыну, йөк төялү.

**НАВЬЮ'ЧИТЬ** *сов.*— к. навьючивать.

**НАВЬЮ'ЧИТЬСЯ** *сов. разг. фам.*— аркага йөк асу, йөк төяү; *навьючился покупками и пошёл домой* — сатып алган әйберләрен аркасына асты да өенә кайтып китте.

**НАВЯЗА'ТЬ** I *сов.*—1. *(намотав, прикрепить, завязать)* бәйләп кую; чорнау, чорнап кую, урау, урап кую; 2. (берникадәр) бәйләү, бәйләп кую; *навязала за месяц пять пар чулок* — бер ай эчендә биш пар оек бәйләгән; 3. *перен.* өстенә йөкләү, көчләп тагу, мәҗбүр итү.

**НАВЯЗА'ТЬ** II *несов.*— к. навязнуть.

**НАВЯЗА'ТЬСЯ** *сов. разг.*— бәйләнү, тыгылу, тыкшыну.

**НА'ВЯЗЕНЬ** *м. обл.*— чабагач тәпәче.

**НАВЯ'ЗНУТЬ** *сов.*— сылану; ябышу, эләгү; *в сетях навязло много тины* — җәтмәгә бик күп бака ефәге ябышкан. ◇ **Навязло в зубах** *перен.*— теш корты булды, теңкәгә тиеп бетте.

**НАВЯ'ЗЧИВОСТЬ** *ж. мн.* нет — бәйләнчеклек, бәйләнчек булу.

**НАВЯ'ЗЧИВО** *нареч.*—йөдәтеп, теңкәгә тиеп; *навязчиво предлагать что-н.*— бернәрсә тәкъдим итеп йөдәтеп бетерү.

**НАВЯ'ЗЧИВЫЙ** —бәйләнчек, бәйләнүчән, сырышкак; *навязчивый человек* — бәйләнчек кеше; *навязчивая мысль* — бәйләнчек фикер (баштан чыкмый торган фикер).

**НАВЯ'ЗЫВАТЬ** *несов.*— к. навязать.

**НАВЯ'ЗЫВАТЬСЯ** *несов.*—1. *разг.* к. навязаться; 2. *страд.* бәйләп куелу, чорнап (бәйләп) куелу, урап (бәйләп) куелу; 3. *страд. перен.* өстенә йөкләнү, көчләп тагылу, мәҗбүр ителү.

**НАВЯ'ЛИВАТЬ** *несов. спец.*— к. навялить.

**НАВЯ'ЛИВАТЬСЯ** *несов. страд. спец.*— (берникадәр) каклану, һавада киптерелү.

**НАВЯ'ЛИТЬ** *сов. спец.*— (берникадәр) каклау, каклап хәзерләп кую, һавада киптерү, һавада киптереп кую.

**НАГАДА'ТЬ** *сов. разг.*— багучылык итеп, алдан сөйләп бирү, күрәзәлек итеп әйтеп бирү.

**НАГА'ДИТЬ** *сов. разг. фам. вульг.*— 1. пычратып бетерү, шакшылап бетерү; 2. *перен. простореч.* яшертен зарар китерү, әшәкелекләр эшләү.

**НАГА'ЙКА** *ж.*— нагайка, камчы.

**НАГА'Н** *м.*— наган (ату коралы).

**НАГА'Р** *м.*— көек, көйрәк (берәр нәрсәнең, мәсәлән, филтәнең, чыраның янып күмерләнгән очы).

**НАГАТИ'ТЬ** *сов. спец.*— гать җәю, гать җәеп чыгу (сазлыкта чыбык, салам һ. б. җәеп юл салу).

**НАГА'ЧИВАТЬ** *несов. спец.*— к. нагатить.

**НАГА'ЧИВАТЬСЯ** *несов. страд. спец.*— гать җәелү.

**НА'ГЕЛЬ** *м. спец.*— нагель (зур агач кадак).

**НАГИБА'ТЬ** *несов.*— к. нагнуть.

**НАГИБА'ТЬСЯ** *несов.*— к. нагнуться.

**НАГИНА'ТЬ** *несов. обл.*— к. нагибать.

**НАГИНА'ТЬСЯ** *несов. обл.*— к. нагибаться.

**НАГИШО'М** *нареч. разг.*— ялангач килеш, шәрә көе, ялангач.

**НАГЛА'ДИТЬ** *сов.* — 1. *разг.* (берникадәр) үтүкләү, үтүкләп кую, үтүкләп чыгу; *нагладила много белья* — бик күп кер үтүкләп куйдым; 2. шомарту.

**НАГЛА'ЖИВАТЬ** *несов.*— к. нагладить.

**НАГЛА'ЖИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. *разг.* (берникадәр) үтүкләнү, үтүкләп куелу; 2. шомартылу.

**НАГЛАЗЕ'ТЬСЯ** *сов. простореч. фам.*— туйганчы карау, туйганчы карап тору.

**НАГЛА'ЗНИК** *м. спец.* —1. күзлек (күзне тузаннан һ. б. саклау өчен кулланыла); 2. өркәк атның йөгәненә тегелгән күн колакча.

**НАГЛАЗУ'РИТЬ** *сов. спец.*— глазурь белән каплау, глазурь белән каплап чыгу, глазурь белән ялтырату, глазурь белән ялтыратып чыгу.

**НАГЛЕ'ТЬ** *несов.*— оятсызлану, оятсызлана бару; *империализм наглеет с каждым днём* — империализм көннән-көн оятсызлана бара.

**НАГЛЕ'Ц** *м.*— оятсыз, вөҗдансыз, нахал, җир бит.

**НАГЛЕЦА'** *ж. мн.* нет, *разг. фам.*— (берникадәр) оятсызлык.

**НАГЛОДА'ТЬСЯ** *сов. простореч.*— туйганчы кимерү.

**НА'ГЛОСТЬ** *ж.*— оятсызлык.

**НАГЛОТА'ТЬСЯ** *разг.*— күп йоту; *наглотаться пыли* — күп тузан йоту.

**НА'ГЛУХО** *нареч.*— томалап, бөтенләй томалап. ◇ **Наглухо застегнуть (одежду)**— кисмиең барлык төймәләрен каптыру.

**НАГЛУШИ'ТЬ** *сов. спец.* — миңгерәтеп (балык) тоту.

**НА'ГЛЫЙ** — оятсыз.

**НАГЛЯДЕ'ТЬ** *сов. обл.*— күп тапкыр күреп сайлап кую, билгеләп кую.

**НАГЛЯДЕ'ТЬСЯ** *сов.*— карап тую, туйганчы карау, күреп тую; *гляжу — не наглядишься* — карыйм-карыйм — карап туя алмыйм.

**НАГЛЯ'ДНО** *нареч.* — ачык, ачык рәвештә, ачык итеп; *чтобы наглядно показать* — ачык итеп күрсәтер өчен.

**НАГЛЯ'ДНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— 1. ачыклык, ачык булу, аңлаешлы булу, аңлашылу; *наглядность доказательства*— дәлилнең ачыклыгы; *для наглядности надо привести пример* — ачык булсын өчен (аңлашылсын өчен) мисал китерергә кирәк; 2. күргәзмәлелек; *наглядность обучения* — укытуның күргәзмәлелеге.

**НАГЛЯ'ДНЫЙ** *книж.*—1. ачык, аңлаешлы, күренеп тора торган, күрсәтмәле; *наглядный пример* — ачык мисал, күрсәтмәле мисал; 2. күргәзмәле; *наглядное обучение* — күргәзмәле укыту; 3. күрсәтмә..., күргәзмә...; *наглядные пособия* — күрсәтмә материаллар. ◇ **Дать наглядное представление** — ачык итеп күрсәтү, күз алдына китерерлек итү.

**НАГЛЯНЦОВА'ТЬ** *сов. спец.*— ялтырату; ялтыратып чыгу, ялтыравык йөгертү.

**НАГНА'ИВАТЬ** *несов. разг.*—к. нагноить.

**НАГНА'ИВАТЬСЯ** *несов.*—1. к. нагноиться; 2. *страд. разг.* эренләндерелү, үлекләндерелү; черетелү, черетеп бетерелү.

**НАГНА'ТЬ** *сов.*—1. җитү, куып җитү, артыннан куып җитү; *не нагнать тебе его* — син аны куып җитә алмассың; *нагнать товарищей в работе* — эштә иптәшләрне куып җитү; 2. куып китерү; *ветер нагнал туч* — җил болытларны куып китерде; 3. (берникадәр) куу, чыгару; *нагнать спирту* — спирт куу; 4. *спец.* сугу, сугып кертү, кидерү, кагу; *нагнать обруч на бочку* — мичкәгә коршау сугу; 5. *разг.* күтәрү; *нагнать цены* — бәяләрне күтәрү; 6. вакыт оту; *машинист нагнал 10 минут* — машинист 10 минут вакыт отты. ◇ **Нагнать тоску** — эч пошыру. **Нагнать страх** — куркыту, курку салу, котны очыру, котны алу. **Нагнать сон** — йоклату, йокымсырату.

**НАГНЕСТИ'** *сов. спец. редко* — к. нагнетать.

**НАГНЕТА'ТЬ** *несов. спец.*—тутыру, кысып тутыру; *нагнетать воздух*— һаваны кысып тутыру. ◇ **Нагнетать давление** *тех.*— басымны арттыру.

**НАГНЕТА'ТЬСЯ** *несов. страд. спец.*— кысып тутырылу, тутырылу; *воздух нагнетается насосом* — һава насос белән тутырыла.

**НАГНИ'ТЬ** *сов.*—1. *простореч.* черү, черең бетү; 2. *обл.* эренли башлау, үлекли башлау, эрен белән каплану.

**НАГНОЕ'НИЕ** *ср. мед.*— эрен җыю, эренләү, үлекләү, үлек җыю.

**НАГНОИ'ТЬ** *сов. разг.*—1. эренләтү,

үлекләтү; 2. (күп итеп) черетү, черетеп бетерү.

**НАГНОИ'ТЬСЯ** *сов.*— эренләү, үлекләү, эрен җыю, үлек җыю, эрен белән каплану, үлек белән каплану.

**НАГНУ'ТЬ** *сов.*—1. ию, бөгү; *нагнуть ветку* — ботакны бөгү; *нагнуть голову* — башны ию; 2. *спец.* (күп итеп) бөгеп кую, (күп итеп) бөгеп хәзерләп кую; *нагнуть много дуг* — күп итеп дуга бөгеп кую.

**НАГНУ'ТЬСЯ** *сов.*— бөгелү, сыгылу.

**НАГОВА'РИВАТЬ** *несов.*—к. наговорить.

**НАГОВА'РИВАТЬСЯ** *несов.*—1. к. наговориться; 2. *страд.* (күп) сөйләнү, артык сөйләнү; 3. *страд.* яла ягылу; 4. *страд.* әфсенләнү, өшкерелү.

**НАГОВЕ'ТЬСЯ** *сов. простореч.*— ач торып җәфа чигү.

**НАГОВО'Р** *м. разг.*—1. *только ед. (действие)* к. наговорить 2, 3; 2. *(клевета)* яла; әләк.

**НАГОВОРИ'ТЬ** *сов.*—1. *разг.* (күп) сөйләү, артык сөйләү, артык сөйләп ташлау; 2. *(наклеветать)* яла ягу; әләкләү; 3. *этногр. обл.* әфсенләү, өшкерү; 4. сөйләүне (пластинкага) яздыру; *наговорить патефонную пластинку* — сөйләүне патефон пластинкасына яздыру.

**НАГОВОРИ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— туйганчы сөйләшү; сөйләшеп тую.

**НАГОВО'РЩИК** *м.*, **НАГОВО'РЩИЦА** *ж.* —1. *разг.* яла ягучы; 2. *обл.* өшкерүче, әфсенче.

**НАГО'Й** *книж.*—1. шәрә, ялангач, япь-ялангач; 2. *перен. поэт.* үсемлексез, ачык, ялангач; 3. *(о деревьях)* яфраксыз.

**НАГОЛЕ'ННЫЙ** *спец.*— тез өсте...-ы; *наголенный щиток* — тез өсте калканчыгы.

**НАГОЛО'** *нареч.:* **вынув сабли наголо**— кылычларны кыныларыннан чыгарып; **остричь голову наголо** — башны такыр итеп кыру; **раздеться наголо** *обл.*— шәрә калу, бөтенләйгә чишенү.

**НАГОЛО'ВНИК** *м. обл.*— 1. (хатын-кызларның) баш киеме; 2. чук (йөгәнгә тагыла торган чук).

**НА'ГОЛОВУ или НА' ГОЛОВУ: разбить наголову** — тар-мар итү, бөтенләй кырып бетерү.

**НАГОЛОДА'ТЬСЯ** *сов. разг.*— ачлыктан җәфалану, ачлыктан җәфа чигү, ачка интегү.

**НАГО'ЛЬНЫЙ** *спец.*— тышсыз, тышланмаган (тун, толып), кайры (тун).

**НАГО'НКА** *ж. мн.* нет —1. к. нагнать 4, 5; 2. ау этләрен өйрәтү.

**НАГОНЯ'Й** *м. разг. фам.:* **дать нагоняй** — шелтәләү, кирәген бирү, арт сабагын укыту; *я получил сегодня нагоняй* — миңа бүген әләкте, минем бүген кирәгемне бирделәр.

**НАГОНЯ'ТЬ** I *несов.*— к. нагнать.

**НАГОНЯ'ТЬ** II *сов.*—1. *разг.* туйганчы куу, куып тую; 2. куып-куып кертү; 3. *охот.* дөрес ауларга өйрәтү (ау этен), дөрес куарга өйрәтү (этне җәнлек куарга).

**НАГОНЯ'ТЬСЯ** I *несов. страд.*—1. куып китерелү; 2. (бернникадәр) куылу, чыгарылу.

**НАГОНЯ'ТЬСЯ** II *сов. простореч.*— туйганчы куу, куып тую; куа-куа арып бетү; *дети нагонялись за бабочками* — балалар күбәләкләрне куа-куа арып беттеләр.

**НА-ГОРА'** *нареч. горн.*— өскә, җир өстенә; *выдать уголь на-гора* — җир өстенә күмер чыгару (шахтадан күмер чыгару).

**НАГОРА'ЖИВАТЬ** *несов. разг.*—к. нагородить.

**НАГОРА'ЖИВАТЬСЯ** *несов. страд. разг. простореч.*— өеп куелу, тәртипсез рәвештә өеп куелу, аударылу.

**НАГОРА'ТЬ** *несов.*— к. нагореть.

**НАГОРЕВА'ТЬСЯ** *сов. разг.*— кайгырып тую, җитәрлек кайгыру.

**НАГОРЕ'ТЬ** *сов.*— көю, көйрәкләнү, күмерләнү; *свеча нагорела* — шәмнең очы күмерләнгән; 2. *безл. разг.* (берникадәр) яну, тотылу; *керосина нагорело немного* — керосин аз тотылган; 3. *безл. разг. фам.* эләгү, кирәген бирү; *нагорит тебе за это* — моның өчен сиңа эләгер.

**НАГО'РНЫЙ** — 1. таулы, калкулы; *нагорный берег Волги* — Волганың таулы яры; *Тибет — нагорная страна* — Тибет — таулы ил; 2. таудагы, таулыктагы, таула, тауларда, таулыкта (була торган); калкулыктагы; калкулыкта була торган; *шум нагорный* — тауларда була торган тавыш.

**НАЙТИ'** I *сов.*— 1. табу, эзләп табу; *я нашёл гриб* — мин гөмбә таптым; *наконец-то я нашёл свои часы* — ниһаять, мин сәгатемне таптым; 2. уйлап табу, ачу; *учёный нашёл новый метод исследования* — галим яңа (фәнни) тикшерү методы уйлап тапты; 3. табу, күрү, сизү; *я не нашёл в его словах ни тени притворства* — аның сүзләрендә мин бернинди дә хәйлә сизмәдем; 4. туры китерү; *я нашёл его дома* — мин аны өйдә туры китердем. ◇ Как вы нашли мой дом?— 1. сез минем өемне ничек таптыгыз (ничек эзләп таптыгыз)? 2. минем өем сезгә ошадымы?
**НАЙТИ'** II *сов.*— 1. бәрелү, барып бәрелү, барып төртелү; *засмотревшись, я нашёл на дерево* — (нәрсәдәндер күземне алмыйча) карап барганда мин агачка барып бәрелдем; 2. очрату, өстенә барып чыгу; *бродя по лесу, я нашёл на выводок* — урманда йөри торгач, мин кош балалары өстенә барып чыктым; 3. каплау; *туча нашла на солнце* — болыт кояшны каплады; 4. җыелу; *нашло много народу* — күп халык җыелды; 5. *разг.* тулу; *дым нашёл в комнату* — бүлмәгә төтен тулды. ◇ Нашла тоска — эч поша. Что это на тебя нашло? — ни булды сиңа?
**НАЙТИ'СЬ** *сов.*— 1. табылу; *потерянная книга нашлась* — югалган китап табылды; 2. аптырап калмау, югалып калмау; *такой человек найдётся при всяких обстоятельствах* — андый кеше теләсә нинди хәлдә дә аптырап калмас. ◇ Я не нашёлся, что ответить — мин бернәрсә дә әйтә алмадым.
**НАКА'З** *м.*— 1. *устар. простореч.* боерык, күрсәтмә; *дать наказ* — боерык бирү; 2. *офиц. устар.* наказ, инструкция; *наказ Екатерины II* — Екатерина II наказы; 3. *полит.* наказ, теләкләр һәм таләпләр; *наказ избирателей* — сайлаучыларның наказы (теләкләре һәм таләпләре).
**НАКАЗА'НИЕ** *ср.*— җәза, җәзалау, җәза бирү; каһәрләү. ◇ Наказание мне (тебе) или сущее наказание, или прямо (или просто) наказание *разг.*— бер бәла булды инде. Что за наказание! *разг.*— бу нинди бәла бу, бу нинди бәла тагы!
**НАКАЗА'ТЬ** *сов.*— 1. җәзалау, җәза бирү; каһәрләү; 2. *устар. простореч.* кушу, боеру; *отец наказал сыну хорошо учиться* — әтисе улына яхшы укырга кушты.
**НАКАЗНО'Й, НАКА'ЗНЫЙ** *устар.*— боерык...-ы, наказ...-ы; наказ язылган; *наказная грамота* — наказ язылган грамота, наказ грамотасы. ◇ Наказной атаман *дореvол.*— казачий гаскәрләрендә билгеләнеп куелган атаман.
**НАКА'ЗЫВАТЬ** *несов.*— к. наказать.
**НАКА'ЗЫВАТЬСЯ** *устар. офиц. страд.*— 1. җәзалану, җәза бирелү; каһәрләнү; 2. кушылу, боерылу.
**НАКА'Л** *м. мн.* нет, *спец.*— 1. *(действие)* к. накалить; 2. накал; *лампочка горит в полный накал* — лампочка тулы накал белән яна. ◇ Белый накал — агарганчы кыздыру (кызу).
**НАКА'ЛИВАНИЕ** *ср. мн.* нет, *тех.*— к. накалить. ◇ Лампочка накаливания — кыздырма электр лампасы.
**НАКА'ЛИВАТЬ** *несов.*— к. накалять.
**НАКА'ЛИВАТЬСЯ** *несов.*—1. к. накаляться; 2. *страд.* кыздырылу, бик нык кыздырылу.
**НАКАЛИ'ТЬ** *сов.*— кыздыру, бик нык кыздыру.
**НАКАЛИ'ТЬСЯ** *сов.*— кызу, бик нык кызу.
**НАКА'ЛКА** *ж. мн.* нет, *спец.*— к. накалить.
**НАКА'ЛЫВАТЬ** *несов.*— к. наколоть.
**НАКА'ЛЫВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. наколоться; 2. *страд.* чәнчеп куелу; кадап куелу.
**НАКАЛЯ'ЕМОСТЬ** *ж. мн.* нет, *тех.*— кызучанлык, кызу дәрәҗәсе.
**НАКАЛЯ'ТЬ** *несов.*— к. накалить.
**НАКАЛЯ'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. накалиться; 2. *страд.* кыздырылу, бик нык кыздырылу.
**НАКАНИФО'ЛИТЬ** *сов. спец.*— к. канифолить.
**НАКАНУ'НЕ** *нареч.*— 1. бер көн элек; *накануне он был совсем здоров* — бер көн элек ул бөтенләй сәламәт иде; 2. ...-га каршы, көненә каршы, алдыннан; *накануне праздника* — бәйрәм көненә каршы, бәйрәм алдыннан.
**НАКА'ПАТЬ** *сов.*— 1. тамызу, тамызып салу; *накапать лекарства в рюмку* — рюмкага дару тамызу; 2. *разг.* тамызып пычрату; *накапать на столе чернилами* — кара тамызып өстәлне пычрату.
**НАКА'ПЛИВАТЬ** *несов.*— к. накопить.
**НАКА'ПЛИВАТЬСЯ** *несов.* — к. накопляться.
**НАКА'ПЧИВАТЬ** *несов.*— к. накоптить 2.
**НАКА'ПЫВАТЬ** I *несов.*— к. накапать.
**НАКА'ПЫВАТЬ** II *несов.*— к. накопать.
**НАКА'РКАТЬ** *сов. простореч.*— каркылдап бәла китерү (һәртөрле тылсымнарга ышанучылар аңлавында).
**НАКА'Т** *м. спец.*— 1. *только ед. (действие)* к. накатать; 2. матча; өрлек; *накат прогнил* — өрлек черегән; 3. (берәр нәрсә өстенә тезелгән) бүрәнәләр, калын такталар; *блиндаж с двойным накатом* — ике кат

бүрәнә тезелгән блиндаж; 4. накат (а. *воен.* орудиенең атканда артка таба хәрәкәтеннән соң алга таба китүе; б. *тех.* кәгазь эшләү машинасында кәгазьне урау механизмы).

**НАКАТА'ТЬ** *сов.*— 1. (берникадәр) тәгәрәтеп китерү, тәгәрәтеп китереп кую; *накатать брёвен* — бүрәнәләр тәгәрәтеп китерү; 2. (берникадәр) тәгәрәтеп ясау, әвәләп ясау, тәгәрәтеп ясап кую; *накатать шариков из глины* — балчыктан шарчыклар тәгәрәтеп ясап кую; 3. тәгәрәтү; *накатать очень много белья* — бик күп кер тәгәрәтү; 4. *фам. шутл.* тиз генә язып ташлау; *накатать заявление* — тиз генә гариза язып ташлау; 5. *спец. тип.* (буяу, җилем һ. б. белән) каплау, накат ясау; *накатать набор* — наборны (буяу белән) каплау; 6. йөреп (юл) салу; *возами накатали дорогу по лугу* — олаулар белән йөреп болын аша юл салганнар.

**НАКАТА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — туйганчы шуу, шуып тую; туйганчы утырып йөрү (машинага, атка һ. б.).

**НАКАТИ'ТЬ** *сов.*— 1. (берникадәр) тәгәрәтеп китерү (китереп кую), тәгәрәтеп кертү, тәгәрәтеп кертеп кую; *накатили бочек в вагон* — вагонга мичкәләр тәгәрәтеп керттеләр; 2. тәгәрәтеп менгерү, тәгәрәтеп менгереп кую; *накатить бочку на телегу* — мичкәне арбага тәгәрәтеп менгерү; 3. *простореч.* барып бәрелү; *накатить на столб* — баганага барып бәрелү. ◇ **Как накатит на него, себя не помнит** *простореч.*— җене килгәндә, ул үзен-үзе белми.

**НАКАТИ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. тәгәрәп килеп бәрелү; *бревно накатилось на ногу* — бүрәнә тәгәрәп килеп аякка бәрелде; 2. *поэт.* килеп бәрелү; килеп каплану, менү; *волна накатилась на берег* — дулкын ярга килеп бәрелде; 3. *поэт.* каплау, каплап алу; *накатилось облако на ясное небо* — аяз күк йөзен болыт каплап алды.

**НАКА'ТКА** *ж. спец.* — 1. *только ед.* (*действие*) к. накатить 1, 2; 2. к. накатать 1, 5; 3. накатка (берәр нәрсәне җилем яки буяу белән каплау өчен кулланыла торган прибор).

**НАКА'ТНИК** *м. спец.*—1. өрлек; 2. к. накатка 3.

**НАКА'ТНЫЙ** *спец.*— бүрәнәләр (калын такталар)...-ы; *накатная настилка* — бүрәнәләр түшәмәсе (мәсәлән, блиндажда).

**НАКА'ТОМ** *нареч. спец.*— тәгәрәтеп.

**НАКА'ТЧИК** *м.*— накатчик (1. берәр нәрсәне тәгәрәтеп төяүче яки китерүче эшче; 2. накат ясаучы эшче).

**НАКА'ТЫВАТЬ** *несов.*— к. накатать, накатить.

**НАКА'ТЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. накатиться; 2. *страд.* тәгәрәтеп китерелү (китереп куелу), тәгәрәтеп кертелү (кертеп куелу); тәгәрәтеп менгерелү, тәгәрәтеп менгереп куелу.

**НАКАЧА'ТЬ** *сов.*— 1. (берникадәр) качать итеп тутыру, качать итеп кую; *накачать воды* — су качать итеп кую; 2. (газ, һава яки сыекча) качать итеп кабарту; *накачать шину* — автомобиль шинын һава качать итеп кабарту; 4. *простореч.* башына туку, өйрәтү.

**НАКАЧА'ТЬСЯ** *сов. разг.*— туйганчы тирбәнү, тирбәнеп туйю.

**НАКА'ЧИВАТЬ** *несов.*— к. накачать.

**НАКА'ЧИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — качать итеп тутырылу; качать итеп кабартылу.

**НАКА'ШИВАТЬ** *несов.*— к. накосить.

**НАКА'ШИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— чабылу, чабып алыну.

**НАКВА'СИТЬ** *сов.*— 1. (*о тесте, напитках*) әчетү, әчетеп кую (берникадәр); 2. (*о капусте*) тозлау, тозлап кую (берникадәр); 3. (*о молоке*) оету, оетып кую (берникадәр).

**НАКВА'ШИВАТЬ** *несов.*— к. наквасить.

**НАКИДА'ТЬ** *сов. разг.*— к. набросать 1.

**НАКИ'ДКА** *ж.*— 1. *разг.* естәмә, өстәү; *десятипроцентная накидка* — ун процент өстәмә; 2. накидка (а. җилкәгә салына торган җиңсез кием; б. мендәр өслеге, мендәр өстенә ябыла торган япма, җәймә).

**НАКИ'ДЫВАТЬ** I *несов.*— к. накидать.

**НАКИ'ДЫВАТЬ** II *несов.*— к. накинуть.

**НАКИ'ДЫВАТЬСЯ** I *несов. страд. разг.*— (күп итеп) ташлану, ыргытылу.

**НАКИ'ДЫВАТЬСЯ** II *несов.*— 1. к. накинуться; 2. *страд.* салыну; өстәлү, арттырылу.

**НАКИ'НУТЬ** *сов.*— 1. салу; *она быстро накинула себе на плечи шерстяной платок* — ул җилкәсенә тиз генә йон шәлен салды; 2. *разг.* өстәү, арттыру; *накинуть рубль на килограмм* — килосына бер сум өстәү.

**НАКИ'НУТЬСЯ** *сов. разг.* — к. наброситься.

**НАКИПА'ТЬ** *несов.*— к. накипеть.

**НАКИПЕ'ТЬ** *сов.* — 1. (*о пене*) кайнаганда өскә күбек җыелу, күбек күтәрелү; 2. (*о накипи*) юшкын утыру.

**НА'КИПЬ** *ж. мн.* нет — 1. (кайнаганда өскә чыккан) күбек; 2. (*осадок на стенках сосуда*) юшкын; касмак.

**НАКИПЯТИ'ТЬ** *сов.*— кайнату, кайнатып кую; *накипятить воды* — су кайнатып кую.

**НАКЛА'ДКА** *ж.*— 1. парик, ясалма чәч; 2. *порт.* накладка (хатын-кыз күлмәгенә матурлык өчен тегелгән бизәк); 3. *только ед.* (*действие*) к. накладывать; 4. ишек биге планкасы (йозак элү өчен куелган атламага кертелә торган планка).

**НАКЛА'ДНО** *нареч. простореч.* — файдасыз, табышсыз; бик кыйбат.

**НАКЛАДНО'Й** — 1. йөгертелгән, ябыштырылган; *ложка накладного серебра* — көмеш йөгертелгән кашык; 2. ябыштырылган, ясалма; *накладные усы* — ябыштырылган (ясалма) мыек. ◇ **Накладные расходы** — өстәмә расходлар.

**НАКЛА'ДЧИК** *м. спец.* — накладчик (1. производствода берәр нәрсәне салып торучы, турылап торучы эшче; 2. *тип.* китаплар баса торган машинага кәгазь салып торучы эшче).

**НАКЛА'ДЫВАТЬ** *несов.* — к. наложить 1, 2, 3, 4, 5, 6.

**НАКЛА'СТЬ** *сов. простореч.* — к. наложить 5, 6.

**НАКЛЁВ** *м. спец.* — 1. *только ед.* (*действие*) к. наклёвывать; 2. чебеш борынлаган урын.

**НАКЛЕВА'ТЬ** *сов.* — 1. чукып ашау, чукып ашап бетерү; 2. чукып әрәм итеп бетерү.

**НАКЛЕВЕТА'ТЬ** *сов.* — к. клеветать.

**НАКЛЁВЫВАТЬ** *несов.* — 1. к. наклевать; 2. *спец.* к. наклюнуть.

**НАКЛЁВЫВАТЬСЯ** *несов.* — к. наклюнуться.

**НАКЛЕ'ИВАТЬ** *несов.* — к. наклеить.

**НАКЛЕ'ИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. *разг.* к. наклеиться; 2. *страд.* ябыштырылу, ябыштырып куелу.

**НАКЛЕ'ИТЬ** *сов.* — 1. ябыштыру, ябыштырып кую; *наклеить марку на конверт* — конвертка марка ябыштыру; 2. (берникадәр) ябыштыру, ябыштырып ясау, ябыштырып ясап кую; *наклеил за день двадцать коробок* — бер көн эчендә егерме тартма ябыштырып ясадым.

**НАКЛЕ'ИТЬСЯ** *сов. разг.* — ябышу; *марка хорошо наклеилась* — марка яхшы ябышты.

**НАКЛЕ'ЙКА** *ж.* — 1. *только ед.* (*действие*) к. наклеить; 2. ябыштырып куелган әйбер (кәгазь һ. б.).

**НАКЛЕПА'ТЬ** I *сов. спец.* — чүкеп ябыштыру (ябыштырып кую), чүкеп ялгау.

**НАКЛЕПА'ТЬ** II *сов. простореч.* — яла ягу.

**НАКЛЁПКА** *ж. спец.* — 1. *только ед.* (*действие*) к. наклепать I; 2. чүкеп ябыштырылган нәрсә (өлеш, кисәк).

**НАКЛЁПЫВАТЬ** *несов. спец.* — к. наклепать I.

**НАКЛЁПЫВАТЬСЯ** *несов. страд. спец.* — чүкеп ябыштырылу, ябыштырып куелу, чүкеп ялгану.

**НАКЛИ'КАТЬ** *сов. устар.* — алдан юрап бәла китерү (һәртөрле дини хорафатларга ышанучылар аңлавынча).

**НАКЛИКА'ТЬ** *несов. устар.* — к. накликать.

**НАКЛО'Н** *м.* — 1. авышлык, сөзәклек; 2. *только ед.* к. наклонение 1.

**НАКЛОНЕ'НИЕ** *ср.* — 1. *только ед.* (*действие*) к. наклонить; наклониться; 2. *грам.* төркемчә.

**НАКЛОНИ'ТЬ** *сов.* — бөгү, ию, сыгу; авыштыру; *наклонить доску* — тактаны авыштыру.

**НАКЛОНИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. иелү, сыгылу; бөгелү, салыну, салынып төшү; *ивы наклонились над водой* — таллар суга таба салынып төшкәннәр; *они наклонились над картой* — алар карта өстенә иелделәр; 2. авышу, янтаю, кыйшаю; *столб наклонился* — багана кыйшайган.

**НАКЛО'ННОСТЬ** *ж. книж.* — 1. ярату, һәвәслек; *он проявлял наклонность к уединению* — ул ялгызлыкны ярата иде; 2. *преимущ. мн.* гадәтләр; *дурные наклонности* — начар гадәтләр; 3. *науч.* авышлык почмагы.

**НАКЛО'ННЫЙ** — авыш, сөзәк; *наклонная плоскость* — авыш яссылык.

**НАКЛОНЯ'ТЬ** *несов.* — к. наклонить.

**НАКЛОНЯ'ТЬСЯ** *несов.* — к. наклониться.

**НАКЛЮ'НУТЬ** *сов. спец.* — борынлый башлау; *цыплёнок наклюнул яйцо* — чебеш борынлый башлаган.

**НАКЛЮ'НУТЬСЯ** *сов.* — 1. к. наклюнуть; 2. *разг. фам.* чиртү; *дельце наклюнулось* — шәп кенә бер эш чиртте.

**НАКЛЯ'УЗНИЧАТЬ** *сов. простореч.* — к. кляузничать.

**НАКОВА'ЛЬНЯ** *ж.* — 1. (*кузнечный станок*) сандал, тимерче сандалы; 2. *анат.* сандал сөяк (колакта).

**НАКОВА'ТЬ** *сов.* — 1. (берникадәр) чүкеп ясау, таптап ясау; 2. *тех.* кыздырып ябыштыру, кыздырып ялгау (металлны). ◇ Наковать жёрнов *спец.* — тегермән ташын тешәү.

**НАКО'ВКА** *ж. спец.* — 1. *только ед.* (*действие*) к. наковать; 2. (*насечка на жёрнове*) теш.

**НАКО'ВЫВАТЬ** *несов.* — к. наковать.

**НАКО'ВЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. (берникадәр) чүкеп ясалу, таптап ясалу; 2. *тех.* кыздырып ябыштырылу, кыздырып ялгану.

**НАКОВЫ'РИВАТЬ** *несов. разг.* — к. наковырять.

**НАКОВЫРЯ'ТЬ** *сов. разг.* — 1. үреп ясау, үреп ясап кую; *наковырять лаптей* — чабаталар үреп ясау; 2. *простореч. шутл.* эшләп ташлау; *ну, что ты там наковырял?* — я, син анда ниләр эшләп ташладың?

**НАКО'ЖНИК** *м.* — 1. *разг.* к. кожник; 2. *спец.* корчаңгы микробы.

**НАКО'ЖНЫЙ** *мед.* — тире...-ы; *накожная болезнь* — тире авыруы.

**НАКОКСОВА'ТЬ** *сов. тех.* — (берникадәр) кокслау, кокслап хәзерләү, кокслап хәзерләп кую.

**НАКОЛА'ЧИВАТЬ** *несов.* — к. наколотить.

**НАКОЛЕ'ННИК** *м.* — 1. (*тёплая повязка*) тез җылыткыч; 2. *спорт.* тез саклагыч; 3. *истор.* тез калканчыгы (борын заманда кылыч яки сөңге һөҗүменнән саклану өчен гаскәриләрнең тезенә кидерелә торган саклагыч).

**НАКОЛЕ'ННЫЙ** *спец.* — тезгә каплана торган, тезгә киелә торган, тезгә бәйли торган.

**НАКОЛОТИ'ТЬ** *сов. разг.* — 1. к. набить 2, 5, 6, 7, 8; 2. җыю; *за зиму-то я тысячу рублей наколотил* — кыш буена мең сум акча җыйдым.

**НАКОЛО'ТЬ** *сов.* — 1. (берникадәр) вату, ватып кую, ваклау, ваклап кую; *наколоть сахару* — шикәр ватып кую; 2. (берникадәр) яру, ярып кую; *наколоть охапку дров* — бер кочак утын ярып кую; 3. сую, суеп кую; *на зиму наколоть свиней* — кышлыкка дуңгызлар суеп кую; 4. к. надколоть 1; 5. чәнчеп ясау; *наколоть узор* —

чәнчеп бизәк ясау; 6. кадау, кадап кую; *бабочку наколоть на доску* — күбәләкне тактага кадап кую; 7. *разг.* керү, кадалу; *наколола руку рыбьей костью* — кулыма балык кылчыгы кадалды.

**НАКОЛО'ТЬСЯ** *сов.*— кадалу; *наколоться на булавку* — булавкага кадалу.

**НАКОЛОШМА'ТИТЬ** *сов. простореч. вульг.*— дөмбәсләп ташлау, тукмап ташлау.

**НАКОЛОШМА'ЧИВАТЬ** *несов. простореч. вульг.*— к. наколошматить.

**НАКО'МКАТЬ** *сов. разг.*— 1. йомарлап бетерү, укмаштырып бетерү; *накомкать бумаги* — кәгазьләрне йомарлап бетерү; 2. *фам.* йомарлап тыгып кую; *накомкать белья в корзинку* — керне кәрзингә йомарлап тыгып кую.

**НАКОНЕ'Ц** — 1. *нареч.* ахырда, актыкта, соңыннан, ниһаять; *и сам догадался наконец* — ниһаять үзе дә сизеп алды; 2. *в знач. союза „и"* — ниһаять; *за кавалерией двигалась пехота, потом артиллерия, наконец сапёры* — кавалерия артыннан пехота, аның артыннан артиллерия, ниһаять сапёрлар бара иде; 3. *ввод. сл.* ниһаять, ахыр чиктә, бара торгач; һич булмаса; *можно, наконец, спросить у товарищей* — ниһаять, иптәшләреннән сорарга мөмкин. ◇ **Наконец-то я увидел тебя!** — сине күрер көнем дә бар икән! **Наконец-то дождались весны** — язны күрер көнебез дә бар икән.

**НАКОНЕ'ЧНИК** *м.*— очлык (мәсәлән, карандаш, таяк очына куела торган нәрсә); *наконечник для карандаша* — карандаш очлыгы.

**НАКОПА'ТЬ** *сов.*— 1. (берникадәр) казу, казып алу; *накопать мешок картошки* — бер капчык бәрәңге казып алу; 2. казып чыгу; *накопать ям* — чокырлар казып чыгу.

**НАКОПИ'ТЬ** *сов.*— 1. аз-азлап җыю; *накопить денег на дорогу* — аз-азлап юллык акча җыю; 2. туплау, җыю; *накопить знаний* — белем туплау, белем җыю.

**НАКОПИ'ТЬСЯ** *сов.* — җыелу, азлап җыелу, туплану.

**НАКОПЛЕ'НИЕ** *ср. только ед. книж.*— 1. (*действие*) к. накопить; 2. тупланыш; *социалистическое накопление* — социалистик тупланыш; 3. җыелган (тупланган, саклыкка куелган) акча һ. б.

**НАКОПЛЯ'ТЬ** *несов.*— к. накопить.

**НАКОПЛЯ'ТЬСЯ** *несов.*— к. накопиться.

**НАКОПТИ'ТЬ** *сов.*— 1. төтәү, сөремләү; *лампа очень накоптила* — лампа бик төтәгән; 2. (берникадәр) ыслау, ыслап хәзерләп кую; каклау, каклап хәзерләп кую; *накоптить окороков* — ыслап окороклар хәзерләп кую.

**НАКОПЫ'ЛЬНИК** *м. спец.*— үрәчә (чана үрәчәсе).

**НАКОРМИ'ТЬ** *сов.*— 1. ашату, туйдыру, туйганчы ашату; 2. (*ребёнка, детёныша своим молоком*) имезү.

**НАКОРЧЕВА'ТЬ** *сов.*: *накорчевать пней* — төп чыгару.

**НАКОРЧЁВЫВАТЬ** *несов.*— к. накорчевать.

**НАКОСИ'ТЬ** *сов.* — (берникадәр) чабу, чабып алу, чабып кую (мәсәлән, печәнне).

**НАКОСИ'ТЬСЯ** *сов.* — арыганчы чабу, туйганчы чабу, чабып тую (мәсәлән, печән).

**НАКО'СТНИЦА** *ж. вет.*— сөяк шеше, сөяк орысы (атларда була торган авыру).

**НАКО'СТНЫЙ** *спец.* — сөяк өстендәге, сөяк өстендә була торган.

**НАКОСТЫЛЯ'ТЬ** *сов. простореч. вульг.*— дөмбәсләп (тукмап) ташлау.

**НА'КОСЬ** *частица, обл.*— мә, мә сиңа, менә сиңа; мә ал; *накось хлебушка, поешь* — мә сиңа икмәк, ашап ал.

**НАКРА'ДЫВАТЬ** *несов.*— к. накрасть.

**НАКРА'ИВАТЬ** *несов.*— к. накроить.

**НАКРА'ИВАТЬСЯ** *несов. страд.*—(берникадәр) киселү, кисеп хәзерләнү, кисеп хәзерләп куелу.

**НАКРА'ПАТЬ** *сов. спец.* — бөрчек-бөрчек итеп буяу.

**НАКРА'ПЫВАТЬ** I *несов.*— сибәләү, сибәләп тору.

**НАКРА'ПЫВАТЬ** II *несов. спец.*— к. накрапать.

**НАКРА'СИТЬ** *сов.*— 1. ягу, буяу; *накрасить губы* — иреннәрне буяу; 2. (берникадәр) буяу, ману, буяп чыгу, манып чыгу; *накрасить пол* — идәнне буяу; *накрасить платье* — күлмәк ману (манып бирер төскә кертү).

**НАКРА'СИТЬСЯ** *сов.*— буяну, ягыну.

**НАКРА'СТЬ** *сов.*— урлап җыю.

**НАКРАХМА'ЛИТЬ** *сов.* — крахмаллау, крахмаллап кую.

**НАКРА'ШИВАТЬ** *несов.*— к. накрасить.

**НАКРА'ШИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. накраситься; 2. *страд.* ягылу, буялу; манылу.

**НАКРЕНИ'ТЬ** *сов.*— 1. авыштыру, янтайту, кыйшайту; 2. *безл.* авышу, янтаю, кыйшаю; *от оседания почвы дом накренило набок* — җир иңү сәбәпле өй бер якка янтайган.

**НАКРЕНИ'ТЬСЯ** *сов.*— янтаю, кыйшаю.

**НАКРЕНЯ'ТЬ** *несов.*— к. накренить.

**НАКРЕНЯ'ТЬСЯ** *несов.*—1. к. накрениться; 2. *страд.* янтайтылу, кыйшайтылу.

**НА'КРЕПКО** *нареч.* — 1. нык итеп, ныклап; *накрепко запереть дверь* — ишекне нык итеп бикләү; 2. *разг.* катгый рәвештә, кискен рәвештә, категорик рәвештә; *накрепко запретить браниться* — сүгенүне катгый рәвештә тыю. ◇ **Крепко-накрепко** — бик нык итеп, бик каты.

**НА'КРЕСТ** *нареч.* — аркылы-торкылы, әвернәсыман итеп. ◇ **Крест-накрест** — аркылы-торкылы, аркылы-торкылы итеп.

**НА'КРИВО** *нареч. простореч. редко* — кыек, янтаеп.

**НАКРИЧА'ТЬ** *сов.* — кычкырыну, акырыну.

**НАКРИЧА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — туйганчы кычкыру, арыганчы кычкыру.

**НАКРОИ'ТЬ** *сов.* —(берникадәр) кисеп кую, кисеп хәзерләп кую; *накроить пиджаков* — пиджаклар кисеп хәзерләп кую.

**НАКРОМСА'ТЬ** *сов. простореч.* — (бер-

нникадәр) кискәләп ташлау, кискәләп бетерү; тураклап ташлау, тураклап бетерү.

**НАКРОШИ'ТЬ** *сов.* — 1. (берникадәр) ваклау, турау, ваклап салу, турап салу; 2. *(насорить крошками)* валчыклар белән чүпләп бетерү, валчыклар кою.

**НАКРУТИ'ТЬ** *сов.* — 1. *(намотать)* (берникадәр) урау, чорнау, урап кую, чорнап кую; 2. *спец.* *(изготовить кручением)* (берникадәр) катып ясау, бөтереп ясау; 3. *простореч. фам.* *(напроказить)* шаянлыклар эшләп ташлау.

**НАКРУ'ЧИВАТЬ** *несов.* — к. накрутить.

**НАКРУ'ЧИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. уралу, чорналу, урап куелу, чорнап куелу; 2. *спец.* (берникадәр) үрелү, үреп хәзерләнү, катылу, катып хәзерләнү, бөтерелү, бөтереп хәзерләнү.

**НАКРЫВА'ТЬ** *несов.* — к. накрыть.

**НАКРЫВА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. накрыться; 2. *страд.* җәелү (мәсәлән, эскәтер).

**НАКРЫ'ТЬ** *сов.* — 1. җәю, ябу, каплау; *накрыть стол скатертью* — өстәлгә эскәтер җәю; *накрыть тюки брезентом* — тюкларны брезент белән каплау; *накрыть кадку доской* — кисмәкне такта белән ябу; 2. *перен. разг.* тоту, кулга алу; өстенә барып чыгу, көтмәгәндә өстенә барып чыгу; *накрыть нарушителя границы* — чик бозучыны тоту. ◇ **Накрыть стол, накрыть на стол** — табын хәзерләү.

**НАКРЫ'ТЬСЯ** *сов.* — ябыну, бөркәнү.

**НАКУДЕ'СИТЬ** *сов. простореч. устар.* — юләрлекләр эшләп ташлау, мәзәкләр эшләп ташлау, әллә нияләр кылану.

**НАКУПА'ТЬ** I *несов.* — к. накупить.

**НАКУПА'ТЬ** II *сов. простореч.* — туйганчы су коендыру.

**НАКУПА'ТЬСЯ** I *несов. страд.* — (берникадәр) сатып алыну, сатып алып куелу.

**НАКУПА'ТЬСЯ** II *сов. разг.* — туйганчы су коену.

**НАКУПИ'ТЬ** *сов.* — (берникадәр) сатып алу, сатып алып кую.

**НАКУРИ'ТЬ** *сов.* — 1. тәмәке төтене белән тутыру; *накурить в комнате* — бүлмәне тәмәке төтене белән тутыру; 2. яндырып хуш ис чыгару; *накурить вереском* — арчан яндырып хуш ис чыгару; 3. *спец.* (берникадәр) куу, куып хәзерләү; *накурить смолы* — сумала куу.

**НАКУРИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — туйганчы тәмәке тарту.

**НАКУРОЛЕ'СИТЬ** *сов. простореч.* — шаярып әкәмәтләр эшләп ташлау.

**НАКУСА'ТЬ** *сов. разг.* — тешләп бетерү; *комары накусали руку* — озынборыннар кулымны тешләп бетерделәр.

**НАКУ'СЫВАТЬ** *несов. разг.* — к. накусать.

**НАКУ'ТАТЬ** *сов. разг.* — кат-кат киендерү, кат-кат киертү; *накутать на ребёнка тёплых вещей* — балага кат-кат җылы кием киертү.

**НАКУ'ШАТЬ** *сов.* — к. наесть.

**НАКУ'ШАТЬСЯ** *сов.* — к. наесться.

**НАЛА'ВЛИВАТЬ** *несов.* — к. наловить.

**НАЛАГА'ТЬ** *несов. книж.* — к. наложить 3, 4, 7, 8.

**НАЛАГА'ТЬСЯ** *несов. страд. книж.* — салыну; *за нарушение правил уличного движения налагается штраф* — урамда йөрү кагыйдәләрен бозган өчен штраф салына.

**НАЛА'ДИТЬ** *сов.* — 1. оештыру, ачып җибәрү; *наладить новое производство* — яңа производство оештыру; 2. көйләү; *наладить плуг* — сабанны көйләү; 3. рәтләү, юлга салу, юлга салып җибәрү, җайлау, җайга салу; *наладить работу в клубе* — клуб эшен юлга салып җибәрү.

**НАЛА'ДИТЬСЯ** *сов.* — 1. җайлану, җайланып китү, юлга салыну, юлга салынып китү; *работа в клубе наладилась* — клубта эшләр җайланып китте; 2. *простореч. неодобр.* гадәтләнеп китү, өйрәнеп китү; *наладилась лиса в курятник ходить* — төлке тавык кетәгенә йөрергә өйрәнеп китте.

**НАЛА'ДЧИК** *м. спец.* — наладчик, көйләүче (машиналарны, приборларны).

**НАЛА'ЖИВАТЬ** *несов.* — к. наладить.

**НАЛА'ЖИВАТЬСЯ** *несов.* — к. наладиться 1.

**НАЛА'ЗИТЬСЯ** *сов.* — (үрмәләп) менеп йөреп арып бетү.

**НАЛАКА'ТЬСЯ** *сов.* — туйганчы эчү (эт, песи турында).

**НАЛАКИРОВА'ТЬ** *сов.* — лаклау, лак белән каплау.

**НАЛАКИРО'ВЫВАТЬ** *несов.* — к. налакировать.

**НАЛА'КОМИТЬСЯ** *сов. разг.* — сыйлану, туйганчы (татлы әйберләр) ашау; *налакомиться конфетами* — туйганчы конфет ашау.

**НАЛГА'ТЬ** *сов.* — к. наврать 1, 2.

**НАЛЕ'ВО** *нареч.* — 1. сулга, сулга таба, сул якка таба; *прохожий свернул налево* — узгынчы сулга (сулга таба) борылды; 2. сулда, сул якта; *налево был дом* — сулда (сул якта) өй бар иде.

**НАЛЕГА'ТЬ** *несов.* — 1. (өстенә) яту, ятып тору; *налегать грудью на стол* — күкрәге белән өстәлгә яту; 2. *разг.* тырышу, тырышып...-у, бар көчне кую, бар көчне куеп...-у; *налегать на математику* — математиканы тырышып өйрәнү; 3. *(теснить, нажимать)* кысу, кысрыклау.

**НАЛЕГКЕ'** *нареч. разг.* — 1. *(без поклажи)* җиңелчә генә, әйберсез, йөксез; 2. *(в лёгкой одежде)* җиңел киемнән, җиңел генә киенеп.

**НАЛЕЖА'ТЬ** *сов. разг.* — озак ятудан (аркага яки башка берәр җиргә) зыян килү; *больной належал себе пролежни на боку* — озак ятудан авыруның янбашы чиләнеп беткән.

**НАЛЕЖА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — туйганчы яту, туйганчы ятып тору, ятып тую.

**НАЛЕЗА'ТЬ** *несов.* — к. налезть.

**НАЛЕ'ЗТЬ** *сов. разг.* 1. үрмәләп менеп сырып алу, үрмәләп менеп каплап алу, сырышу; *на яблоню налезли муравьи* — алмагачка кырмыскалар сырышканнар; 2. сыю, таман булу; *шапка налезла на голову* — бүрек башка сыйды.

**НАЛЕПИ'ТЬ** *сов.* — 1. *разг.* ябыштыру,

ябыштырып кую; *налепить объявление на стену* — стенага белдерү ябыштыру; 2. (берникадәр) әвәләү, әвәләп ясау, әвәләп ясап кую; *мальчик налепил из глины птичек* — малай балчыктан кошлар әвәләп ясаган. ◇ Налепить нос (*кому*) — к. нос.

**НАЛЕПЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. налепить.

**НАЛЕПЛЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. ябыштырылу, ябыштырып куелу; 2. әвәләнү, әвәләп ясалу, әвәләп ясап куелу.

**НАЛЁТ** *м.* — 1. (*действие*) к. налететь 1, 2, 4, 5; 2. (*нападение*) һөҗүм; баскын; 3. куның (берәр нәрсә өстенә кунган юка катлау, мәсәлән, корым); 5. *мед.* эренле катлау (ангина белән авырганда тамакта була). ◇ С налёта или с налёту — 1. очып барганда, йөгереп барганда, чабып барганда; туктамыйча, туктамастан; 2. *перен. разг. неодобр.* алдан хәзерләнмичә, уйламастан, уйлап-нитеп тормыйча.

**НАЛЕТА'ТЬ** I *несов.* — к. налететь.

**НАЛЕТА'ТЬ** II *сов. авиац.* — очу; *самолёт налетал десять тысяч километров* — самолёт ун мең километр очкан; *лётчик безаварийно налетал 270 часов* — лётчик авариясез 270 сәгать очкан.

**НАЛЕТА'ТЬСЯ** *несов.* — арыганчы очу, очып тую.

**НАЛЕТЕ'ТЬ** *сов.* — 1. (*наброситься*) ыргылу, ташлану; 2. (*внезапно напасть*) кинәт һөҗүм итү; 3. (*наткнуться с разбегу*) барып бәрелү, килеп бәрелү; 4. көтмәгәндә өстенә барып чыгу, тап булу (берәр күңелсезлеккә); *налететь на неприятельский отряд* — көтмәгәндә дошман отряды өстенә барып чыгу; 5. (*налететь стаей*) ябырылып очып килү; 6. очып килеп (кереп) куну, очып килеп (кереп) тулу; *с улицы налетело много пыли* — урамнан бик күп тузан (очып) кереп кунган; 7. кубу, күтәрелү; *налетел ветер* — җил күтәрелде. ◇ Налететь на выговор — шелтәгә эләгү.

**НАЛЁТОМ** *нареч. простореч. фам.* — очраклы рәвештә генә, узганда-барганда гына, узышлый гына, барышлый гына.

**НАЛЁТЧИК** *м.* — талаучы, баскынчы, йортлар басучы.

**НАЛЁТЫВАТЬ** *несов. авиац.* — к. налетать II.

**НАЛЕ'ЧЬ** *сов.* — к. налегать.

**НАЛИ'В** *м. спец.* — 1. *только ед.* (*действие*) к. налить; 2. (*созревание*) өлгерү, җитү, җитешү, пешү; 3. пешү вакыты, пешә торган вакыт, җитү вакыты, җитә торган вакыт, өлгерү вакыты, өлгерә торган вакыт; *теперь самый налив яблокам* — хәзер алмаларның нәкъ пешә торган вакыты; 4. (*отверстие в бочке*) авыз; 5. *вет.* шеш (ат аягында була торган авыру). ◇ Белый налив — ак алма (алманың бер сорты).

**НАЛИВА'ТЬ** *несов.* — к. налить.

**НАЛИВА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. налиться; 2. *страд.* (берникадәр) тутырылу; салыну, салып куелу; түгелү; коелу, коеп ясалу.

**НАЛИ'ВКА** *ж.* — төнәтмә (җимеш салып төнәтелгән аракы).

**НАЛИВНО'Й** — 1. *нар.-поэт.* (*о плодах*) тулып пешкән; 2. (су) коеп ясала торган; *наливной каток* — (су) коеп ясала торган каток; 3. (сыекчалар) сала торган; *наливной бак* — (сыекчалар) сала торган бак; 3. *тех.* сыекчалар салып йөртә торган; *наливная баржа* — сыекчалар салып йөртә торган баржа; 4. *тех.* су...-ы; *наливная мельница* — су тегермәне.

**НАЛИЗА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — туйганчы ялану, ялаиып тую, туйганчы ялау, ялап тую.

**НАЛИ'М** *м. зоол.* — жумба, шамбы (балык).

**НАЛИ'МИЙ** — жумба...-ы; шамбы...-ы; *налимья печёнка* — жумба бавыры.

**НАЛИНЕВА'ТЬ, НАЛИНОВА'ТЬ** *сов.* — сызу, сызып кую.

**НАЛИПА'ТЬ** *несов.* — к. налипнуть.

**НАЛИ'ПНУТЬ** *сов.* — сылану, ябышу.

**НАЛИТОГРАФИ'РОВАТЬ** *сов.* — литографиядә бастыру.

**НАЛИ'ТОК** *м. обл.* — аткый, атабай, сака.

**НАЛИ'ТЬ** *сов.* — 1. (берникадәр) тутыру; тутырып кую, салу, салып кую; *налить стакан молока* — бер стакан сөт салу; *налить водою бочку* — мичкәгә су тутыру; 2. түгү; *налить воды на пол* — идәнгә су түгү; 3. (*изготовить посредством литья*) кою, коеп ясау (берникадәр).

**НАЛИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. тулу, керү; *вода налилась в лодку* — көймәгә су кергән; 2. җитү, пешү, өлгерү; *груши уже налились* — грушалар җиткән инде. ◇ Глаза налились кровью — күзләрен кан баскан.

**НАЛИЦО'** *нареч. в знач. сказ. книж.* — күз алдында; бар; *доказательства налицо* — дәлилләр бар.

**НАЛИ'ЧЕСТВОВАТЬ** *несов. книж. устар. канц.* — булу; *наличествуют все признаки преступления* — җинаятьнең барлык билгеләре бар.

**НАЛИ'ЧИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — барлык. ◇ При наличии — булса, булганда.

**НАЛИ'ЧНИК** *м. спец.* — йөзлек, наличник (кисеп бизәк төшерелгән һәм тәрәзә яки ишеккә тышкы яктан беркетеп куелган тар планка).

**НАЛИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. к. наличие; 2. булган акча,...-гы акча; *кассовая наличность* — кассадагы акча, кассада булган акча. ◇ Велика ли наличность товаров в складе? — складта күпме товар бар?

**НАЛИ'ЧНЫЙ** — 1. булган, кулдагы, кулда булган; *наличный капитал* — кулдагы (кулда булган) капитал; *наличные деньги* — кулда булган акча; 2. *только мн. в знач. сущ.* саф акча, кулда булган акча. ◇ Наличный расчёт *фин.* — саф акча белән түләү, кулдан түләү. За наличный расчёт — саф акчага. Наличный состав армии — армиянең хәзерге составы.

**НАЛО'БНИК** *м. спец.* — 1. (*повязка*) маңгай бәйләвече; 2. (*в конской узде*) маңгайча.

**НАЛО'БНЫЙ** *спец.* — маңгай...-ы; *налобная повязка* — маңгай бәйләвече.

**НАЛОВИ'ТЬ** *сов.* — (берникадәр) тоту, тотып алу (мәсәлән, балык).

**НАЛОВЧИ'ТЬ** *сов. разг. редко* — остарту, күнектерeп җибәрү.

**НАЛОВЧИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — остару, остарып китү, җитезләнү.

**НАЛО'Г** *м.* — салым, түләү, налог.

**НАЛО'ГОВЫЙ** — 1. салым...-ы, салымнар...-ы, түләү...-ы, түләүләр...-ы, налог...-ы; налоглар...-ы; *налоговый сбор* — салымнар җыемы; 2. салым(нар) алу...-ы, түләү(ләр) алу...-ы; налог(лар) алу...-ы; салым(нар) җыю...-ы, түләү(ләр) җыю...-ы, налог(лар) җыю...-ы; *налоговая система* — салым(нар) җыю системасы; 3. салым (түләү, налог) җыю эшләрен алып бара торган; *налоговый аппарат* — налог җыю эшләрен алып бара торган аппарат; 4. салым(нар)-дан килә торган, түләү(ләр)дән килә торган, налог(лар)дан килә торган; *налоговые доходы* — салым(нар)дан килә торган доходлар.

**НАЛОГОПЛАТЕ'ЛЬЩИК** *м. офиц.* — салым (налог) түләүче.

**НАЛОГОСПОСО'БНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *право* — салым (налог) түләргә тиеш булу (закон буенча).

**НАЛОГОСПОСО'БНЫЙ** — салым (налог) түләргә тиеш булган (закон буенча).

**НАЛОЖИ'ТЬ** *сов.* — 1. өстенә кую, өстенә салу; *наложить прозрачную бумагу на рисунок для копировки* — күчермәсен алу өчен рәсем өстенә үтә күренмәле кәгазь кую; 2. *спец.* каплау; *наложить лак на картину* — рәсемне лак белән каплау; 3. *офиц.* басу, салу; *наложить печать* — печать басу; *наложить резолюцию* — резолюция салу; 4. *перен.* калдыру; *наложить отпечаток* — эз калдыру; 5. (берникадәр) өю, өеп кую; *наложить подушек на кровать* — кроватька мендәрләр өеп кую; 6. тутыру, төяү; *наложить корзину белья* — бер кәрзин кер тутыру; 7. *офиц. книж.* салу, бирү; *наложить штраф* — штраф салу; *наложить взыскание* — шелтә бирү; 8. *книж.* өскә алу, йөкләү, салу; *наложить на себя бремя забот* — үз өстенә авыр мәшәкатьләр алу; 9. *вульг.* тукмау, дөмбәсләү, кыйнау. ◇ **Наложить на себя руки** *устар.* — үзен-үзе үтерү. **Наложить гипс** — гипска салу. **Наложить бинт** — бинт белән бәйләү, бинтлау.

**НАЛО'Й** (или **АНАЛОЙ**) *м. церк.* — налой (чиркәүдә иконалар яки китаплар куя торган биек өстәл).

**НАЛО'ЖНИЦА** *ж. книж. устар.* — кәнизәк.

**НАЛОКО'ТНИК** *м. истор.* — терсәк калканчыгы (терсәккә киелә торган калканчык).

**НАЛОМА'ТЬ** *сов.* — 1. (берникадәр) сындыру; *ветер наломал много сучьев* — җил бик күп ботакларны сындырган; 2. *(ломая, наготовить)* сындырып хәзерләү. ◇ **Наломать бока** *простореч.* — кабыргаларын санау.

**НАЛО'ПАТЬСЯ** *сов. простореч. вульг.* — тыгыну, тыгынып тую (күп ашау мәгънәсендә).

**НАЛОЩИ'ТЬ** *сов.* — ялтыратып чыгу.

**НАЛУЩИ'ТЬ** *сов. разг.* — 1. ... кабыгы белән чүпләп бетерү; *налущить семечек* — көнбагыш кабыгы белән чүпләп бетерү; 2. кузагыннан әрчү; *налущить гороху* — борчакны кузагыннан әрчү.

**НАЛЮБОВА'ТЬСЯ** *сов.* — 1. сокланып туйганчы карап тору; 2. *(с отрицанием не)* сокланып (карап) туя алмау; *не налюбуюсь на детей* — балаларга карап туя алмыйм.

**НАЛЯ'ПАТЬ** *сов. простореч. пренебр.* — ничек җитте шулай эшләп ташлау; аннан моннан эшләп ташлау; эштер-өштер китереп ташлау.

**НАМАГНИ'ТИТЬ** *сов. спец.* — магнитлау, магнитландыру.

**НАМАГНИ'ЧИВАТЬ** *несов. спец.* — к. намагнитить.

**НАМА'ЗАТЬ** *сов.* — 1. ягу, сөртү, сылау; *намазать кусок хлеба маслом* — ипи сыныгына май ягу, бер телем ипигә май ягу; 2. *разг.* пычрату; *намазать на столе* — өстәлне пычрату; 3. *разг. пренебр. (о рисунке)* буяштыргалау; *(написать неразборчиво)* сызгалау; 4. *разг. фам.* буяу; *намазать губы* — иреннәрне буяу.

**НАМА'ЗАТЬСЯ** *сов.* — 1. пычрану, буялу; *намазался салом* — туң майга пычранган; 2. *разг. фам.* буяну, ягыну.

**НАМА'ЗЫВАТЬ** *несов.* — к. намазать.

**НАМА'ЗЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. намазаться; 2. *страд.* ягылу, сөртелү, сылану.

**НАМАЗЮ'КАТЬ** *сов. фам. шутл. детск.* — пычратып бетерү, буяп бетерү.

**НАМАЛЕВА'ТЬ** *сов. обл.* и *разг. пренебр.* — к. малевать.

**НАМАЛЕВА'ТЬСЯ** *сов. разг. пренебр.* — буяну, ягыну.

**НАМА'ЛЫВАТЬ** *несов.* — к. намолоть.

**НАМА'ЛЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — тарттырылу, тарттырып алыну (он турында).

**НАМАРА'ТЬ** *сов. разг. пренебр.* — 1. *(о рисунке)* ясаштыргалап ташлау, начар гына ясап ташлау; 2. *(о письме)* сызгалау, сызгалап ташлау (начар гына язып ташлау).

**НАМАРИНОВА'ТЬ** *сов.* — (берникадәр) мариновать итеп кую, маринадлап кую; *намариновать банку грибов* — бер банка гөмбә маринадлап кую.

**НАМАРИНО'ВЫВАТЬ** *несов.* — к. намариновать.

**НАМА'СЛИВАТЬ** *несов. разг.* — к. намаслить.

**НАМА'СЛИТЬ** *сов. разг.* — майлау, май ягу, май сөртү.

**НАМАСТИ'ТЬ** *сов. старин.* — хуш исле май сөртү, хуш исле мазь сөртү.

**НАМА'ТЫВАТЬ** *несов.* — к. намотать.

**НАМА'ТЫВАТЬСЯ** I *несов.* — 1. к. намотаться 1; 2. *страд.* урап куелу, чорнап куелу.

**НАМА'ТЫВАТЬСЯ** II *несов. простореч.* — к. намотаться II.

**НАМА'ЧИВАТЬ** *несов.* — к. намочить.

**НАМА'ЧИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. *разг.* чылану, юешләнү; 2. *страд.* чылатылу, юешләтелү.

**НАМА'ЩИВАТЬ** I *несов.* — к. намостить.

**НАМА'ЩИВАТЬ** II *несов. старин.* — к. намастить.

**НАМА'ЩИВАТЬСЯ** I *несов. страд.* — түшәлү, җәелү.

**НАМА'ЩИВАТЬСЯ** II *несов. страд. старин.* — хуш исле май сөртелү, хуш исле мазь сөртелү.

**НАМА'ЯТЬСЯ** *сов. простореч.* — арып бетү, тенкә корып бетү.

**НАМЕ'ДНИ** *нареч. простореч.* — күптән түгел генә, шушы арада гына, бая, баягынак.

**НАМЕ'ДНИШНИЙ** *простореч.* — күптән түгел генә булган, шушы арада гына булган.

**НАМЕЖЕВА'ТЬ** *сов. спец.* — ызан салып чыгу, межа салып чыгу.

**НАМЕЖЁВЫВАТЬ** *несов. спец.* — к. намежевать.

**НАМЕЖЁВЫВАТЬСЯ** *несов. страд. спец.* — ызан салып чыгылу, межа салып чыгылу.

**НАМЁК** *м.* — 1. ишарә, кинаят, читләтеп әйтелгән сүз; 2. *перен.* эз, әсәр; *даже намёка нет на это* — моның хәтта эзе дә (әсәре дә) юк.

**НАМЕКА'ТЬ** *несов.* — читләтеп әйтү, читләтеп сөйләү, кинаяле сөйләү. ◇ **Я сразу догадался, на что он намекает** — аның тел төбе кая барганын шунда ук сизеп алдым.

**НАМЕКНУ'ТЬ** *однокр.* — сиздерү, сиздереп кую, беллерү; читләтеп әйтеп кую.

**НАМЕЛИ'ТЬ** I *сов. простореч.* — ваклау, ваклап чыгу.

**НАМЕЛИ'ТЬ** II *сов.* — акбурлау, акбур сөртү.

**НАМЕ'НИВАТЬ** *несов.* — к. наменять.

**НАМЕНЯ'ТЬ** *сов.* — (берникадәр) алыштыру, алыштырып алу.

**НАМЕРЕВА'ТЬСЯ** *несов.* — теләү, уйлау,...-макчы булу, ниятләү, исәп итү, исәп тоту, чамалау, чамалап тору, җыену; *намереваюсь уехать* — китәргә чамалыйм.

**НАМЕ'РЕНИЕ** *ср.* — ният, исәп, теләк.

**НАМЕ'РЕННО** *нареч.* — белеп, уйлап, юри.

**НАМЕ'РЕННЫЙ** — белеп эшләнгән, уйлап эшләнгән, алдан белеп эшләнгән, алдан уйлап эшләнгән, юри эшләнгән.

**НАМЕРЗА'ТЬ** *несов.* — к. намёрзнуть.

**НАМЁРЗНУТЬ** *сов.* — 1. кату, күп (булып) кату; *на ступеньках намёрзло много льда* — баскычларга бик күп боз каткан; 2. *разг.* туңу, өшү, кату; *руки сильно намёрзли* — кулларым бик нык туңды.

**НАМЁРЗНУТЬСЯ** *сов. разг.* — туңу, туңып бетү, кату, катып бетү, өшү, өшеп бетү.

**НАМЕ'РИВАТЬ** *несов.* — к. намерить.

**НАМЕ'РИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — үлчәп чыгарылу, үлчәп алыну.

**НАМЕ'РИТЬ** *сов. разг.* — 1. үлчәп кую, үлчәп алу; *намерить 20 метров сукна* — 20 метр постау үлчәп кую (алу); 2. үлчәп белү; *от дороги до реки намерили 200 метров* — юлдан елгага тикле 200 метр икәнен үлчәп белделәр.

**НА'МЕРТВО** *нареч. спец.* — нык итеп, ачылмаслык итеп, сүтмәслек итеп.

**НАМЕ'РЯТЬ** — к. намерить.

**НАМЕСИ'ТЬ** *сов.* — (берникадәр) изү, изеп кую, изеп хәзерләп кую; *намесить теста* — камыр изеп кую. ◇ **Намесить грязи** *разг.* — аяклар белән пычрак керту (ташу).

**НАМЕСТИ'** *сов.* — 1. (берникадәр) себереп өеп кую; *намести кучу мусора* — чүпне себереп өеп кую; 2. (өреп китереп) өю; *снегу намело видимо-невидимо* — чиксез күп кар өйгән.

**НАМЕ'СТНИК** *м.* — наместник (1. *книж. устар.* урынбасар, аерым бурычлар йөкләнгән кеше; 2. *истор.* патша Россиясендә Кавказ, Урта Азия кебек ерак өлкәләрне идарә итүче; 3. *истор.* Россиядә Екатерина II заманында — бер яки берничә губерна башлыгы — генерал-губернатор; 4. *истор.* борынгы Русьта — җирле идарә башлыгы; 5. *церк.* митрополит урынбасары яки монастырь башлыгының ярдәмчесе).

**НАМЕ'СТНИЦА** *ж.* — 1. *истор.* наместник хатыны; 2. *церк.* хатын-кызлар монастыре башлыгының ярдәмчесе.

**НАМЕ'СТНИЧЕСТВО** *ср. истор.* — 1. наместниклык (наместник тарафыннан идарә ителә торган өлкә); 2. наместниклык вазифасы, наместниклык урыны.

**НАМЕ'СТО** *нареч. простореч. обл.* — к. вместо.

**НАМЁТ** *м.* — 1. намёт (а. *рыболов.* озын сапка утыртылган капчыксыман җәтмә, б. шлемда һәм калканда була торган яфраксыман бизәк; в. казакларда: атның сикереп чабуы); 2. *обл.* (*сугроб*) көрт.

**НАМЕТА'ТЬ** I *несов.* — к. намести.

**НАМЕТА'ТЬ** II *сов.* — 1. (берникадәр) салу, кую; *наметать пять стогов* — биш кибән кую; 2. чәчү; *рыба наметала икры* — балык уылдык чәчкән; 3. *разг.* өйрәтү, күнектерү, остарту; *наметать глаз* — күзне күнектерү.

**НАМЕТА'ТЬ** III *сов. порт.* — күкләп чыгу, типчеп чыгу.

**НАМЕТА'ТЬСЯ** *сов. простореч.* — өйрәнү, күнегү, остару.

**НАМЕ'ТИТЬ** I *сов.* — 1. билге (тамга) салу, билге (тамга) кую; билгеләр салып чыгу; *наметить брёвна клеймом* — бүрәнәләргә билге салып чыгу; 2. өстән-өстән генә сызу, өстән-өстән генә сызып чыгу; *наметить контур детали* — детальнең контурын өстән-өстән генә сызып чыгу; 3. күрсәтү, төшерү; *наметить на плане направление дороги* — планда юлның юнәлешен күрсәтү, юлның юнәлешен планга төшерү.

**НАМЕ'ТИТЬ** II *сов.* — 1. *разг.* төзәү, төбәү; *наметил в голову, а попал в руку* — башына төзәдем, ә кулына тидердем; 2. билгеләү, билгеләп кую; *его наметили кандидатом в председатели* — аны председательлеккә кандидат итеп билгеләгәннәр; 3. уйлап кую, чамалап кую, ният итү, ниятләү; *наметить поездку в Крым* — Кырымга барырга ният итү.

**НАМЕ'ТИТЬСЯ** I *сов.* — билгеләнү, сизелү, беленү.

**НАМЕ'ТИТЬСЯ** II *сов. разг.* — к. метиться I.

**НАМЁТКА** I *ж. порт.* — 1. күкләп чыгу, типчеп чыгу; 2. ак жеп, күкләү җебе.

**НАМЁТКА** II *ж. разг.* — уйланылган план, алдан уйлап куелган план.

**НАМЁТКА** III *ж. рыболов.* — намётка, сәк (озын сапка утыртылган капчыксыман җәтмә).

**НАМЁТЫВАТЬ** *несов.* — к. наметать II.

**НАМЁТЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. салыну, куелу (кибән, эскерт турында); 2. чәчелү (уылдык турында).

**НАМЕЧА'ТЬ** I *несов.* — к. наметить I.

**НАМЕЧА'ТЬ** II *несов.* — к. наметить II во 2, 3 знач.

**НАМЕЧА'ТЬСЯ** I *несов.* — 1. к. наметиться I; 2. *страд.* билге (тамга) салыну, билге (тамга) куелу; күрсәтелү.

**НАМЕЧА'ТЬСЯ** II *несов. страд.* — 1. билгеләнү, билгеләп куелу; 2. уйлап куелу, чамалап куелу.

**НАМЕЧТА'ТЬСЯ** *сов.* — озак вакыт хыяллану, озак вакыт хыялланып тору, туйганчы хыяллану.

**НАМЕША'ТЬ** *сов.* — катнаштыру, кушып тугылау.

**НАМЕ'ШИВАТЬ** I *несов.* — к. намесить.

**НАМЕ'ШИВАТЬ** II *несов.* — к. намешать.

**НАМИНА'ТЬ** *несов.* — к. намять.

**НАМИНА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — (берникадәр) изеп куелу, изеп хәзерләп куелу.

**НАМОГИ'ЛЬНЫЙ** — кабер...-ы; кабер өстенә куелган; *намогильный памятник* — кабер ташы, кабер өстенә куелган һәйкәл.

**НАМОЗО'ЛИТЬ** *сов. разг. фам.*: **намозолить глаза** — туйдырып бетерү, теңкәгә тиеп бетү.

**НАМОКА'ТЬ** *несов.* — чылану, җебү, юешләнү.

**НАМО'КНУТЬ** *сов.* — к. намокать.

**НАМО'Л** *м. мн.* нет, *спец.* — тарттырылган онның күләме.

**НАМОЛА'ЧИВАТЬ** *несов.* — к. намолотить.

**НАМОЛА'ЧИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — сугылу (иген турында).

**НАМОЛОТИ'ТЬ** *сов.* — сугып алу, сугып кую (иген турында).

**НАМОЛО'ТЬ** *сов.* — тарттырып кую, тарттырып алу; *намолоть мешок муки* — бер капчык он тарттырып алу. ◇ **Намолол чепухи** (вздору и т. п.) — юк-барны сөйләде шунда.

**НАМО'РДНИК** *м.* — борынчык.

**НАМОРИ'ТЬ** *сов.* — 1. үтереп бетерү, агулап үтереп бетерү; *наморить крыс* — күселәрне агулап үтереп бетерү; 2. сүндерү; *наморить углей* — күмер сүндерү; 3. талдыру, талдырып хәзерләү; *наморить хрену* — керән талдыру; 4. *разг. (утомить)* ардырып бетерү, алҗытып бетерү; өшәндереп бетерү.

**НАМОРИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — арып бетү, өшәнеп бетү.

**НАМО'РЩИТЬ** *сов.* — җыеру, җыерып кую.

**НАМО'РЩИТЬСЯ** *сов.* — йөзне чытыкландыру, чырай сыту, чырай бозу.

**НАМОСТИ'ТЬ** *сов. спец.* — 1. җәю, түшәү, җәеп чыгу, түшәп чыгу; *намостить пол* — идән түшәү; 2. басма (күпер) салу.

**НАМОТА'ТЬ** *сов.* — урау, чорнау, урап кую, чорнап кую; *намотать нитки на катушку* — җепне кәтүккә чорнап кую. ◇ **Намотать себе на ус** — колакка киртеп кую, мыекка чорнап кую (истә тоту, хәтергә алу мәгънәсендә).

**НАМОТА'ТЬСЯ** I *сов.* — уралу, уралып бетү, чорналу, чорналып бетү.

**НАМОТА'ТЬСЯ** II *сов. просторечо.* — арып бетү, алҗып бетү, хәлдән таю.

**НАМО'ТКА** *ж. спец.* — 1. *только ед. (действие)* к. намотать; 2. *(моток)* йомгак.

**НАМОЧИ'ТЬ** *сов.* — 1. чылату, җебетү, юешләтү, чылатып кую, җебетеп кую; *намочить бельё* — кер җебетү; *намочить яблок на зиму* — кышлыкка алма җебетеп кую; 2. *разг.* (*наплескать*) чәчрәтеп чылатып бетерү, юешләп бетерү.

**НАМУДРИ'ТЬ** *сов. разг.* — буташтырып бетерү, бутап бетерү.

**НАМУ'ДРСТВОВАТЬ** *сов. разг. шутл.* — к. намудрить.

**НАМУ'СЛИТЬ, НАМУСО'ЛИТЬ** *сов. просторечо.* — төкерекләү, төкерекләп бетерү.

**НАМУ'СОРИТЬ** *сов. разг.* — чүпләү, чүпләп бетерү (мәсәлән, идәнне).

**НАМУТИ'ТЬ** *сов. разг.* — 1. *(наделать мути)* болганчыкландырып бетерү; 2. *перен. фам. (наделать беспокойства)* буталчыклык тудыру, тынычсызлык тудыру, шаушу куптару.

**НАМУ'ЧИТЬ** *сов. разг.* — ардырып бетерү, җәфалап бетерү, интектереп бетерү.

**НАМУ'ЧИТЬСЯ** *сов. разг.* — җәфаланып бетү, җәфа чигү, интегеп бетү, ару, арып бетү.

**НАМЫ'В** *м. геол.* — китерелмә, дуен балчык (елга ярының агым сулар алып килгән туфрактан, комнан һ. б. барлыкка килгән өлеше).

**НАМЫВА'ТЬ** *несов.* — к. намыть.

**НАМЫВА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. *просторечо.* к. намыться; 2. *страд.* китереп өелү; юылу, бик чиста итеп юып куелу.

**НАМЫ'КАТЬСЯ** *сов. просторечо.* — күп авырлыклар күрү, күп кыенлыклар күрү, күп кайгы-хәсрәт чигү, азап чигү. ◇ **Намыкался по белу свету** *просторечо.* — илдән илгә йөреп интегеп бетте.

**НАМЫ'ЛИВАТЬ** *несов.* — к. намылить.

**НАМЫ'ЛИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. *разг.* к. намылиться; 2. *страд.* сабын сөртелү.

**НАМЫ'ЛИТЬ** *сов.* — сабынлау, сабын сөртү. ◇**Намылить голову** — к. голова.

**НАМЫ'ЛИТЬСЯ** *сов. разг.* — сабынлану, сабын сөртенү.

**НАМЫ'ТЬ** *сов.* — 1. *(добыть, промывая)* юып алу, юып аеру, юып табу; *намыть золотого песку* — алтын комын юып аеру; 2. *обл.* к. настирать; 3. (*нанести течением*) китереп өю; 4. *просторечо.* (*чисто*

*вымыть)* чиста итеп юу, чиста итеп юып кую.

**НАМЫ'ТЬСЯ** *сов. просторечн.* — чиста итеп юыну, туйганчы юыну.

**НАМЯКА'ТЬ** *несов.* — к. намякнуть.

**НАМЯ'КНУТЬ** *сов.* — җебеп йомшару, җебеп изерәү.

**НАМЯ'ТЬ** *сов.* — 1. *(разминая, приготовить)* изеп кую, изеп хәзерләп кую (берникадәр); 2. *(помять)* таптау, таптап бетерү (берникадәр); 3. *(давлением, трением причинить боль)* кырдыру, кырдырып чиләндерү, суйдыру. ◇ **Намять бока** *просторечн.* — кабыргаларын санау (кыйнап ташлау мәгънәсендә).

**НАНА'И, НАНА'ЙЦЫ** *мн.* — нанайлар, нанай халкы (Амур елгасы бассейнында яшәүче халык; элеккеге исеме — гольдлар).

**НАНА'ШИВАТЬ** *несов.* — к. наносить II.

**НАНЕСТИ'** I *сов.* — 1. (берникадәр) китерү, китереп өю, китереп тутыру; *нанести подарков* — бүләкләр китерү; 2. (берникадәр) нартеп керү, ташу; *нанести грязи в комнату* — бүлмәгә пычрак нартеп керү; 3. өю, китереп өю; *ветер нанёс сугроб* — җил көрт китереп өйгән; 4. *просторечн.* бәрдерү, илтеп бәрдерү, китереп бәрдерү; *разгорячённые лошади нанесли экипаж на столб* — ярсыган атлар экипажны баганага илтеп бәрдерделәр; 5. илтеп ташлау; *лодку ветром нанесло на мель* — җил көймәне сайлыкка илтеп ташлаган; 6. төшерү; *нанести на карту направление новой дороги* — яңа юлның юнәлешен картага төшерү. ◇ **Нанести визит** — визит ясау. **Нанести рану** — яралау. **Нанести обиду** — хәтер калдыру. **Нанести удары** — берничә тапкыр сугу, кыйнау. **Нанести ущерб** — зыян китерү.

**НАНЕСТИ'** II *сов.* — (берникадәр) йомырка салу; *курица за лето нанесла 150 яиц* — тавык бер җәй эчендә 150 йомырка салды.

**НАНИЗА'ТЬ** *сов.* — (берникадәр) (җепкә) тезү, тезеп кую; *нанизать жемчуг на нить* — җепкә энҗе тезү.

**НАНИЗУ'** *нареч. просторечн.* — түбәндә, аста.

**НАНИ'ЗЫВАТЬ** *несов.* — к. нанизать.

**НАНИ'ЗЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — (җепкә тезелү, тезеп куелу.

**НАНИМА'ТЕЛЬ** *м. офиц.* — яллаучы.

**НАНИМА'ТЬ** *несов.* — к. нанять.

**НАНИМА'ТЬСЯ** *несов.* — к. наняться.

**НА'НКА** *ж. мн.* нет — нанка (тукыманың бер төре).

**НА'НОВО** *нареч. разг.* — яңадан.

**НАНО'С** *м.* — китерелмә, дуен балчык (су агымы, җил китереп өйгән нәрсәләр катламы).

**НАНОСИ'ТЬ** I *несов.* — к. нанести I.

**НАНОСИ'ТЬ** II *сов.* — китерү, ташу, ташып кую.

**НАНОСИ'ТЬСЯ** I *несов. страд.* — 1. китерелү, ташып куелу; 2. китереп өелү; 3. төшерелү.

**НАНОСИ'ТЬСЯ** II *сов. разг.* — арыганчы ташу, ташып ару, ташый-ташый арып бетү.

**НАНО'СНЫЙ** — 1. китерелмә..., китереп өелгән (җил яки су агымы белән китерелгән); *наносный песок* — китерелмә ком; 2. *перен. разг.* очраклы рәвештә барлыкка килгән, очраклы рәвештә туган, үзенә хас булмаган; *наносные идеи* — очраклы рәвештә барлыкка килгән идеяләр; 3. *перен. просторечн. устар.* гайбәт...-ы; *всякий знает, что всё это наносные слова* — бу сүзләрнең гайбәт икәнлеген һәркем дә белә.

**НАНЮ'ХАТЬ** *сов.* — 1. *разг. (найти по запаху)* исе белән табу, исеннән табу; 2. *просторечн.* иснәп пычрату; *миску нанюхала собака* — аш табагын эт иснәп пычратты.

**НАНЮ'ХАТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. *(понюхать вдоволь)* иснәп туйю, туйганчы иснәү; 2. *(нюхая, опьянеть)* иснәп исерү, исергәнче иснәү.

**НАНЮ'ХИВАТЬ** *несов.* — к. нанюхать.

**НАНЮ'ХИВАТЬСЯ** *несов.* — к. нанюхаться.

**НАНЯ'НЧИТЬСЯ** *сов. разг. ирон. укор.* — баланы (авыруны һ. б.) карап туеп бетү.

**НАНЯТО'Й** *разг.* — ялланган; ялланып эшләүче.

**НАНЯ'ТЬ** *сов.* — 1. яллау; *нанять рабочих* — эшчеләр яллау; 2. хак түләп, вакытлыча файдалануга алу; *нанять квартиру* — хак түләп, вакытлыча файдалануга квартира алу.

**НАНЯ'ТЬСЯ** *сов.* — яллану.

**НАОБЕЩА'ТЬ** *сов. разг.* — күпне ышандыру, күп вәгъдәләр бирү. ◇ **Наобещать с три короба** — тау хәтле вәгъдә бирү, әлләниләр вәгъдә итү, алтын таулар ышандыру.

**НАОБОРО'Т** *нареч.* — киресенчә, кирегә. ◇ **Надеть фуражку наоборот** — фуражканы алдын артка кию.

**НАОБУ'М** *нареч.* — уйламыйча, уйлапнитеп тормастан, дуамал.

**НАОДЕКОЛО'НИТЬСЯ** *сов. просторечн.* — к. одеколониться.

**НАОКО'ННЫЙ** *спец.* — тәрәзә йөзлеге...-ы; тәрәзә башындагы; *наоконные украшения* — тәрәзә башындагы бизәкләр, тәрәзә йөзлеге бизәкләре.

**НАОРА'ТЬ** *сов. разг. фам.* — к. накричать.

**НАОРА'ТЬСЯ** *сов. просторечн.* — к. накричаться.

**НАОСТРИ'ТЬ** I *сов.* — үткенләү, чарлау.

**НАОСТРИ'ТЬ** II *сов. разг.* — үткен сүзләр сөйләп ташлау, тапкыр сүзләр әйтеп ташлау.

**НАО'ТМАШЬ** *нареч.* — кизәнеп; *ударить наотмашь* — кизәнеп сугу.

**НАОТРЕ'З** *нареч.* — катгый рәвештә, кискен рәвештә, категорик формада, кырт кисеп.

**НАО'ХАТЬСЯ** *сов. разг.* — туйганчы ухылдау, ухылдап туеп бетү.

**НАОХО'ТИТЬСЯ** *сов. разг.* — ауда йөреп туеп бетү.

**НАПА'ДАТЬ** *сов.* — (бик күп) коелу.

**НАПАДА'ТЬ** I *несов.* — к. напасть I.

**НАПАДА'ТЬ** II *несов.* — к. напа́дать.

**НАПАДЕ'НИЕ** *ср.* — 1. һөҗүм, һөҗүм

иту; 2. *спорт.* һөҗүмчеләр (футбол уенында — һөҗүм итүче уенчылар).

**НАПА'ДКИ** *ед.* нет — бәйләнү, бәрелү; гаеп ташлау.

**НАПА'ИВАТЬ** I *несов.* — к. напоить.

**НАПА'ИВАТЬ** II *несов.* — к. напаять.

**НАПА'ИВАТЬСЯ** I *несов. страд.* — 1. эчерелү, туйганчы эчерелү; 2. исергәнче эчерелү.

**НАПА'ИВАТЬСЯ** II *несов. страд.* — паять итеп ябыштырылу, коеп ябыштырылу.

**НАПА'КОСТИТЬ** *сов. простореч.* — 1. (*напачкать*) пычратып бетерү, шакшылап бетерү; 2. (*перепортить*) бозу, бозып бетерү; 3. (*повредить*) әшәкелек эшләү, зыян китерү, зарар китерү.

**НАПА'КОСТНИЧАТЬ** *сов. разг.* — к. напакостить 3.

**НАПА'ЛЗЫВАТЬ** *несов.* — к. наползти.

**НАПА'ЛМ** *м.* — напалм (яндыргыч катнашма хәзерләүдә куерткыч сыйфатында кулланыла торган матдә; напалм дип еш кына яндыргыч катнашманың үзенә дә әйтәләр).

**НАПА'ЛЫВАТЬ** *несов.* — к. наполоть.

**НАПА'РИТЬ** *сов.* — 1. парда пешерү; *напарить репу* — шалканны парда пешерү; 2. чабу; *напарил спину в бане* — мунчада аркамны чаптым.

**НАПА'РИТЬСЯ** *сов. разг.* — туйганчы чабыну.

**НАПА'РНИК** *м. спец.* — напарник, кулдаш; *шофёры-напарники* — напарник шофёрлар.

**НАПА'РЫВАТЬ** I *несов. простореч.* — к. напороть I.

**НАПА'РЫВАТЬ** II *несов. простореч.* — к. напороть II.

**НАПА'РЫВАТЬСЯ** I *несов. простореч.* — к. напороться I.

**НАПА'РЫВАТЬСЯ** II *несов. простореч. вульг.* — к. напороться II.

**НАПАСА'ТЬ** *несов. обл.* — к. напасти 1.

**НАПАСА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. *простореч.* к. напастись 1; 2. *страд. обл.* хәзерләп куелу.

**НАПАСТИ'** *обл.* — 1. (*запасти*) хәзерләү, хәзерләп кую (берникадәр); 2. озак кына көтүлектә йөртеп, яхшы ашату; *нужно хорошенько напасти коней* — атларны озак кына көтүлектә йөртеп, яхшы ашатырга кирәк.

**НАПАСТИ'СЬ** *сов. простореч.* — 1. (*припасти*) җитәрлек итеп хәзерләү, җитәрлек итеп хәзерләп кую; 2. (*с отрицанием*) житкерә алмау, төткәрә алмау, хәзерләп өлгерә алмау, хәзерләп өлгертә алмау; 2. *обл.* (*попастись вдоволь*) көтүлектә йөреп туйганчы ашау.

**НАПА'СТЬ** I *сов.* — 1. (*наброситься, атаковать*) һөҗүм итү, ташлану, ябырылу; 2. *разг.* (*придраться*) бәйләнү; 3. очрату, туры китерү; *напал на интересную книгу* — кызыклы китап очраттым. ◇ Напала тоска — кинәт эчем поша башлады. Напасть на след — эзенә төшү.

**НАСМЕ'ШНИК** *м.*, **НАСМЕ'ШНИЦА** *ж. разг.* — мыскыл итүчән, мыскыл итәргә яратучан, кешедән көләргә яратучан.

**НАСМЕ'ШНИЧАТЬ** *несов. разг.* — мыскыл итү, мыскыллау, (кешедән) көлү; (кешедән) көлеп сөйләү, мыскыл итеп көлү, мәсхәрәләп көлү.

**НАСМЕЯ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. *(вдоволь посмеяться)* туйганчы көлү; 2. *(надругаться)* мәсхәрәләп көлү, мыскыллап көлү.

**НАСМОЛИ'ТЬ** *сов.*— 1. сумалалау, сумала сөртү; *насмолить верёвку* — бауга сумала сөртү, бауны сумалалау; 2. *простореч.* тәмәке төтене белән тутыру; *насмолить в комнате* — бүлмәне тәмәке төтене белән тутыру.

**НА'СМОРК** *м.*— томау (авыру).

**НАСМОТРЕ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. күп күрү; *насмотреться всяких чудес* — һәртөрле кы-

зыклы нәрсәләрне күп күрү; 2. *чаще с отриц. или со словами: не могу, не можешь;* карап тую; *не могу насмотреться на эту картину* — бу картинаны карап туя алмыйм.

**НАСМО'ТРЩИК** *м.* — к. надсмотрщик.

**НАСНЕЖИ'ТЬ** *сов. обл.* — 1. кар кертү, кар ташу; *наснежили в избе* — өйгә кар керткәннәр (мәсәлән, аякка ябыштырып); 2. *безл. обл.* бик күп кар яву; *ночью наснежило* — төнлә бик күп кар яуган.

**НАСНИМА'ТЬ** *сов. разг.* — (берникадәр) төшерү, төшереп алу, фотога төшерү; *фотограф наснимал разных видов* — фотограф төрле күренешләр төшереп алган.

**НАСНЯ'ТЬ** *сов. разг.* — к. наснимать.

**НАСОБА'ЧИТЬСЯ** *сов. простореч.* — остарып житү, өйрәнеп житү, этләнеп житү.

**НАСОБИРА'ТЬ** *сов. разг.* — к. насбирать.

**НАСОВА'ТЬ** *сов. разг.* — тыгу, тутыру; *насовать конфет во все карманы* — барлык кесәләргә конфет тутыру.

**НАСОВЕ'ТОВАТЬ** *сов. разг.* — киңәш бирү, киңәшләр бирү.

**НАСО'ВЫВАТЬ** *несов.* — 1. *разг.* к. насовать; 2. *простореч.* к. насунуть.

**НАСО'ВЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. *просторечь.* к. насунуться; 2. *страд.* тутырылу.

**НАСОЛИ'ТЬ** *сов.* — 1. *разг.* (*пересолить*) күп итеп тоз салу, тозны кирәгеннән артык салу; 2. (берникадәр) тозлау, тозлап кую; *насолить огурцов на зиму* — кышлыкка кыяр тозлау; 3. *перен. разг. фам.* (*сделать неприятность*) канга тоз салу, ачуын китерү; *насолить всем* — барысының да канына тоз салу.

**НАСОРИ'ТЬ** *сов. разг.* — чүпләү, чүпләп бетерү (чүп белән).

**НАСОРТИРОВА'ТЬ** *сов. разг.* — сортларга аеру, сортларга аерып кую, сортларга аерып чыгу.

**НАСОРТИРО'ВЫВАТЬ** *несов.* — к. насортировать.

**НАСО'С I** *м. тех.* — насос (сыекча яки газ суырта яки сиптерә торган механизм).

**НАСО'С II** *м. с.-х.* — аңкау шеше (хайваннарда була торган авыру).

**НАСОСА'ТЬ** *сов. разг.* — 1. суыртып тутыру; *насосать бензину в бочку* — мичкәгә бензин суыртып тутыру; 2. имеп зарар китерү, имеп зыян китерү.

**НАСОСА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. туйганчы иму, имеп тую; *ребёнок насосался и спит* — бала имеп туйган да йоклый; 2. туйганчы суыру, эчү; *комар насосался крови* — озынборын туйганчы кан эчкән.

**НАСО'СЧИК** *м. спец.* — насоста эшләүче.

**НАСО'ХНУТЬ** *сов. разг.* — 1. ябышып кибү; *насохла грязь на колёсах* — тәгәрмәчләргә пычрак ябышып кипкән; 2. кору, корып бетү; *в лесу насохло много берёз* — урманда бик күп каен корыган.

**НАСОЧИНИ'ТЬ** и **НАСОЧИНЯ'ТЬ** *сов. разг. ирон.* — (начар) язу, (начар) язып чыгару (әдәби яки музыкаль әсәр турында); 2. ялган сөйләү, уйлап чыгару, үзеннән чыгарып сөйләү.

**НАСОЧИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — үтеп керү; *в трюм насочилась вода* — трюмга су үтеп кергән.

**НАСПА'ТЬ** *сов. простореч.* — йоклап юлыгу, йоклап тару; *спал и беду наспал* — йоклап бәлагә юлыктым, йоклап бәлагә тарыдым.

**НАСПА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — туйганчы йоклау, йоклап тую.

**НА'СПЕХ** *нареч.* — ашыгып, тиз-тиз генә, тиз, ашыгычлык белән, тиз арада, аннан-моннан гына.

**НАСПИ'ННИК** *м. истор.* — арка саклагыч (борын заманда кылыч яки сөңге һөҗүменнән саклану өчен гаскәриләрнең аркага кия торган саклагычы).

**НАСПИРТОВА'ТЬ** *сов.* — спиртлау, спирт сеңдерү.

**НАСПИРТОВА'ТЬСЯ** *сов.* — спиртлану, спирт сеңү.

**НАСПИРТО'ВЫВАТЬ** *несов.* — к. наспиртовать.

**НАСПИРТО'ВЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. наспиртоваться; 2. *страд.* спиртландырылу, спирт сеңдерелү.

**НАСПЛЕ'ТНИЧАТЬ** *сов.* — гайбәт сату.

**НАСПЛЕ'ТНИЧАТЬСЯ** *сов. разг.* — туйганчы гайбәт сату, гайбәт сатып тую.

**НАСПО'РИТЬСЯ** *сов. разг.* — туйганчы дәгъвалашу, туйганчы бәхәсләшү, туйганчы тарткалашу, туйганчы сүз көрәштерү, дәгъвалашып тую, бәхәсләшеп тую, тарткалашып тую, сүз көрәштереп тую.

**НАСТ** *м.* — бозлак, кар кабыгы (епшек көннән соң кар өстенә каткан юка боз).

**НАСТАВА'ТЬ** *несов.* — к. настать.

**НАСТАВИ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — үгетләү характерында булу, нәсихәт бирү характерында булу.

**НАСТАВИ'ТЕЛЬНЫЙ** — үгетләү...-ы, нәсихәт бирү...-ы; киңәш бирә торган, үгетли торган; *наставительный тон* — үгетләү тоны.

**НАСТА'ВИТЬ I** *сов.* — 1. *разг.* кую, куеп чыгу; *наставить сторожей* — сакчылар кую; 2. тезеп чыгу, тезеп кую; *наставить много мебели* — бик күп мебель тезеп кую; 3. озынайту, ялгап озынайту; *наставить рукава* — җиңнәрне ялгап озынайту; 4. *разг.* төзәү, төбәү, юнәлтү; *наставить револьвер* — револьвер төзәү. ◇ Наставить рога — иргә хыянәт итү. Наставить нос — к. нос.

**НАСТА'ВИТЬ II** *сов. книж. устар.* — үгетләү, үгет бирү; *наставить юношу* — егетне үгетләү. ◇ Наставить на ум — акыл өйрәтү. Наставить на путь истинный — дөрес юлга кертү, дөрес юлга бастыру.

**НАСТА'ВКА** — 1. *только ед. разг.* (*действие*) к. наставить; 2. *порт. спец.* ялгау; 3. *грам. редко* алкушымча.

**НАСТАВЛЕ'НИЕ** *ср.* — 1. *только ед. книж. устар.* (*действие*) к. наставить II; 2. (*нравоучение*) үгет, нәсихәт; 3. *офиц.* (*инструкция*) кулланма, күрсәтмә, инструкция.

**НАСТАВЛЯ'ТЬ I** *несов.* — к. наставить I.

**НАСТАВЛЯ'ТЬ II** *несов. книж. устар.* — к. наставить II.

**НАСТАВЛЯ'ТЬСЯ I** *несов. страд.* — 1. те-

зеп куелу; 2. ялгап озынайтылу; 3. төзәлү, төбәлү.

**НАСТАВЛЯ'ТЬСЯ** II *несов. страд. книж. устар.*— үгет бирелү, киңәш бирелү.

**НАСТА'ВНИК** *м.*, **НАСТА'ВНИЦА** *ж. книж. устар.* — җитәкче, акыл бирүче; укытучы, тәрбияче.

**НАСТА'ВНИЧЕСТВО** *ср. мн.* нет, *книж. устар.* — җитәкчелек, җитәкче хезмәте, тәрбияче хезмәте.

**НАСТАВНО'Й** *спец.*— 1. ялгап озынайтылган, ялгаулы; *наставные рукава* — ялгап озынайтылган (ялгаулы) җиңнәр; 2. *физ.* өстәмә; *наставная труба* — өстәмә труба.

**НАСТА'ВОК** *м. порт. простореч.* — к. наставка 2.

**НАСТА'ИВАТЬ** I *несов.*— к. настоять I.

**НАСТА'ИВАТЬ** II *несов.*— к. настоять II.

**НАСТА'ИВАТЬСЯ** I *несов.*—1. к. настояться I; 2. *страд.* төнәтелү.

**НАСТА'ИВАТЬСЯ** II *несов. разг. редко* — к. настояться II.

**НАСТАЛИ'ТЬ** *сов. обл. спец.* — кыздырып ябыштыру.

**НАСТА'ТЬ** *сов. книж.*— 1. җитү, килеп җитү; *настала зима* — кыш җитте, кыш килеп җитте; 2. урнашу; *настала тишина* — тынлык урнашты.

**НАСТЕГА'ТЬ** *сов.*— 1. *спец.* типчү, типчеп кую; *настегать вату на подкладку*— эчлеккә мамык типчеп кую; 2. *спец.* (берникадәр) сыру, сырып кую, сырып хәзерләп кую; *настегать несколько одеял* — берничә юрган сырып кую; 3. *простореч.* камчылау, чыбыркылау, суктыру.

**НАСТЁГИВАТЬ** *несов.*— к. настегать.

**НАСТЁГИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— 1. типчелү, типчеп куелу; 2. (берникадәр) сырылу, сырып куелу, сырып хәзерләп куелу.

**НА'СТЕЖЬ** *нареч.*— төбенә кадәр ачык, бөтенләй ачык, шар ачык (ишек, тәрәзә һ. б. турында); *окна были настежь* — тәрәзәләр шар ачык иде; *настежь отворяют дверь* — ишекне шар ачып куялар.

**НАСТЕЛИ'ТЬ** *сов. простореч.*— к. настлать.

**НАСТЕ'ННЫЙ** — стена...-ы, стенага эленә торган; *настенный календарь* — стена календаре.

**НАСТИГА'ТЬ** *несов.*— к. настичь.

**НАСТИ'ГНУТЬ** — к. настичь.

**НАСТИ'Л** *м. спец.*— 1. *только ед. спец. (действие)* к. настлать; 2. түшәмә.

**НАСТИЛА'ТЬ** *несов.*— к. настлать.

**НАСТИЛА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— җәелү, җәеп куелу, түшәлү, түшәп куелу.

**НАСТИ'ЛКА** *ж.*— 1. *только ед. (действие)* к. настлать; 2. к. настил 2.

**НАСТИ'ЛОЧНЫЙ** *тех.*— түшәүгә китә торган, түшәлә торган; *настилочные доски* — түшәлә торган такталар.

**НАСТИ'ЛЬЩИК** *м. спец.*— җәюче, түшәүче; *настильщик паркета* — паркет җәюче.

**НАСТИРА'ТЬ** *сов. разг.*— 1. (кер) уып кую, (кер) юып кую (берникадәр); *настирать корзину белья* — бер кәрзин кер юып кую; 2. *простореч.* (*хорошо выстирать)* (керне) яхшы итеп уып кую, (керне) яхшы итеп юып кую.

**НАСТИ'РЫВАТЬ** *несов.*— к. настирать.

**НАСТИ'РЫВАТЬСЯ** *несов. страд.*— юып куелу, уып куелу (кер турында).

**НАСТИ'ЧЬ, НАСТИ'ГНУТЬ** *сов.* — куып җитү, куып җитеп тоту, куып җитеп тотып алу; *настигнуть беглецов* — качкыннарны куып җитеп тотып алу. ◇ **Врагов настигла злая кара** — дошманнар каты җәза алды.

**НАСТЛА'ТЬ** *сов.*— җәеп кую, түшәп кую.

**НАСТО'Й** — 1. к. настойка; 2. *апт.* настой.

**НАСТО'ЙКА** *ж.*— 1. настойка, төнәтмә (җимеш яки үлән салып төнәтелгән аракы); *вишнёвая настойка* — чия салып төнәтелгән аракы; 2. *апт.* настойка.

**НАСТО'ЙЧИВО** *нареч.*— каты, нык, үз сүзендә нык торып.

**НАСТО'ЙЧИВОСТЬ** *ж. мн.* нет — үз сүзендә нык тору, әйткәнендә нык тору, үз дигәнен булдыру.

**НАСТО'ЙЧИВЫЙ** — 1. үз сүзендә нык торучан, үз дигәнен булдыручан, әйткәнендә нык тора торган; нык; *настойчивый человек* — үз сүзендә нык торучан кеше, үз дигәнен булдыручан кеше; *настойчивый характер* — нык характер; 2. катгый, категорик; *настойчивое требование* — катгый таләп.

**НАСТО'ЛЬ** *нареч. книж. устар.*— к. настолько.

**НАСТО'ЛЬКО** *нареч.*— шул кадәр, шул хәтле, шул дәрәҗәдә. ◇ **Не настолько...** — дәрәҗәдә үк... түгел; *он не настолько умён, чтобы понять это* — ул моны аңларлык дәрәҗәдә үк акыллы түгел. **Настолько-то** — ул кадәр генә; *настолько-то я сам понимаю по-французски* — ул кадәр генә мин үзем дә французча аңлыйм.

**НАСТО'ЛЬНЫЙ** — 1. өстәл...-ы; өстәлгә куела торган; *настольная лампа* — өстәлгә куела торган лампа; 2. кулланма..., һәрвакыт кирәк булган, һәрвакыт кирәк була торган, һәрвакыт кирәкле; *настольная книга* — кулланма китап.

**НАСТОРА'ЖИВАТЬ** *несов.*— к. насторожить.

**НАСТОРА'ЖИВАТЬСЯ** *несов.*— к. насторожиться.

**НАСТОРОЖЕ'** *нареч.* — сагаеп, сак; *мы всегда настороже* — без һәрвакыт сагаеп торабыз (сакбыз); *быть настороже* — сак булу.

**НАСТОРОЖИ'ТЬ** *сов. охот.*— корып кую; *насторожить капкан* — капканны корып кую. ◇ **Насторожить уши или слух** — 1. *(о животном)* колак торгызу, колак шәмрәйтү; 2. *перен. (о человеке)* колак торгызу, игътибар белән тыңлый башлау, кызыксынып тыңлый башлау. **Насторожить внимание** — игътибарны көчәйтү, игътибар белән тыңлый башлау, кызыксынып тыңлый башлау.

**НАСТОРОЖИ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. сагаю; эсәрү; *лошадь насторожилась* — ат эсәрде; 2. колак торгызу, игътибар белән тыңлый

башлау; *я насторожился, услышав, что говорят обо мне* — мин, үзем турында сүз барганын ишеткәч, игътибар белән тыңлый башладым.

**НАСТОЯ'НИЕ** *ср. книж.* — катгый таләп, катгый үтенеч.

**НАСТОЯ'ТЕЛЬ** *м. церк.* — **1.** монастырь башлыгы (ирләр монастыреның башлыгы); 2. өлкән поп (чиркәүдә).

**НАСТОЯ'ТЕЛЬНИЦА** *ж. церк.* — монастырь башлыгы (хатын-кызлар монастыреның башлыгы).

**НАСТОЯ'ТЕЛЬНО** *книж.* — таләпчән рәвештә, катгый рәвештә.

**НАСТОЯ'ТЕЛЬНЫЙ** — **1.** катгый, таләпчән; *настоятельное требование* — катгый таләп (катгый рәвештә куелган таләп); **2.** котылгысыз, бик зур; *настоятельная нужда* — бик зур ихтыяҗ (бик кирәк булу).

**НАСТОЯ'ТЕЛЬСТВО** *ср. церк.* — монастырь башлыгының хезмәте, монастырь башлыгының хезмәт урыны.

**НАСТОЯ'ТЬ** I *сов.* — үз сүзендә тору, үзенекен итү, ... -дертү; *настоять на выдаче денег* — акчаны бирдертү.

**НАСТОЯ'ТЬ** II *сов.* — салып тонәтү; *настоять водку на вишне* — аракыга чия салып тонәтү.

**НАСТОЯ'ТЬСЯ** I *сов.* — **1.** чыгып җитү; *чай ещё не настоялся* — чәй әле чыгып җитмәгән; **2.** тонәп җитү; *водка ещё не настоялась* — аракы әле тонәп җитмәгән.

**НАСТОЯ'ТЬСЯ** II *сов. разг.* — озак вакыт басып тору.

**НАСТОЯ'ЩИЙ** — **1.** хәзерге, бу, шушы; *в настоящую минуту* — хәзерге минутта; **2.** *в знач. сущ. ср. мн.* нет, *книж.* бүгенге көн, хәзерге заман; *работать для настоящего* — бүгенге көн өчен эшләү; **3.** чын; *настоящий художник* — чын художник; **4.** тиешле; *вы давайте цену настоящую* — сез тиешле бәясен бирегез. ◇ **По-настоящему** *разг.* — чынлап, тиешенчә. **Настоящее время** *грам.* — хәзерге заман. **Настоящий дурак** — шыр тиле.

**НАСТРА'ГИВАТЬ** *несов.* — к. настрогать.

**НАСТРА'ГИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — ышкылап куелу, ышкылап хәзерләнеп куелу.

**НАСТРАДА'ТЬСЯ** *сов.* — бик күп җәфа чигү, бик күп газап чигү; күп кайгы-хәсрәт чигү.

**НАСТРА'ИВАТЬ** I *несов.* — к. настроить I.

**НАСТРА'ИВАТЬ** II *несов.* — к. настроить II.

**НАСТРА'ИВАТЬСЯ** *несов.* — **1.** к. настроиться; **2.** *страд.* көйгә салыну; корылу; **3.** *страд.* котыртылу.

**НАСТРА'ЧИВАТЬ** *несов.* — к. настрочить 1, 3.

**НАСТРАЩА'ТЬ** *сов. простореч.* — куркытып бетерү.

**НАСТРА'ЩИВАТЬ** *несов. простореч.* — к. настращать.

**НАСТРЕ'ЛИВАТЬ** *несов.* — к. настрелять.

**НАСТРЕЛЯ'ТЬ** *сов.* — 1. (берникадәр) ату; *настрелять зайцев* — куяннар ату; **2.** *простореч. (о деньгах)* бурычка акча алу (берникадәр).

**НАСТРЕЛЯ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — туйганчы ату, атып тую.

**НАСТРИГА'ТЬ** *несов.* — к. настричь.

**НАСТРИ'ЧЬ** *сов.* — **1.** *(о шерсти)* кырку, кыркып алу (берникадәр); **2.** *(о бумаге)* кискәләү, кискәләп ташлау (берникадәр).

**НАСТРОГА'ТЬ** *сов.* — (берникадәр) ышкылап кую, ышкылап хәзерләп кую.

**НА'СТРОГО** *нареч. разг.* — каты итеп, катгый рәвештә. ◇ **Строго-настрого** — бик каты, бик каты итеп, катгый рәвештә, бик нык итеп.

**НАСТРОЕ'НИЕ** *ср.* — кәеф, күңел, настроение; рух; *весёлое настроение* — шат күңел; *упадочные настроения в буржуазной литературе* — буржуаз әдәбиятта төшенке настроениеләр; *в обществе бодрое настроение* — җәмгыятьнең рухы күтәренке. ◇ **На бирже настроение вялое** — биржада эшләр шәптән түгел.

**НАСТРО'ЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — к. настроение.

**НАСТРО'ИТЬ** I *сов.* — **1.** *разг.* (бик күп) төзү, (бик күп) салу; (бик күп) кору; *настроить домов* — (бик күп) йорт салу.

**НАСТРО'ИТЬ** II *сов.* — **1.** көйләү, көйгә салу; *настроить рояль* — рояльне көйләү; **2.** кору; *настроить приёмник на длинную волну* — алгычны озын дулкынга кору. ◇ **Настроить против** *кого-н.* — кемгә дә булса каршы котырту. **Настроить** *кого-н.* **в свою пользу** — кемне дә булса үз ягыңа аудару.

**НАСТРО'ИТЬСЯ** *сов. разг.* — **1.** *(о муз. инструменте, радиоприёмнике)* көйгә салыну; корылу; **2.** корып җибәрү; **3.** җыену; *я настроился ехать на Кавказ* — мин Кавказга барырга җыендым.

**НАСТРО'ЙЩИК** *м.* — көйләүче, көйгә салучы (музыкаль инструментларны).

**НАСТРОЧИ'ТЬ** *сов.* — **1.** *порт.* (берникадәр) каю, каеп чыгу; **2.** *разг.* тиз генә язу, тиз генә язып алу, тиз генә язып ташлау; *настрочить письмо* — тиз генә хат язып ташлау; **3.** *разг.* котырту; *его настрочили приятели, ему самому бы не догадаться* — аны дуслары котырткан, югыйсә аның башына да килмәгән булыр иде.

**НАСТРЯ'ПАТЬ** *сов. разг.* — **1.** (берникадәр) пешерү, пешереп хәзерләп кую, пешереп кую; *настряпать блинов* — белен пешереп кую; **2.** *перен. фам. неодобр.* язып ташлау, сызгалап ташлау, сызгалап бирү; *настряпать заявление* — гариза язып ташлау.

**НАСТУДИ'ТЬ** *сов. просторeч.* — суытып бетерү; *настудить комнату* — бүлмәне суытып бетерү.

**НАСТУЖА'ТЬ** *несов. просторeч.* — к. настуживать.

**НАСТУ'ЖИВАТЬ** *несов. просторeч.* — к. настудить.

**НАСТУ'КАТЬ** *сов. разг.* — **1.** суккалап кайда барлыгын табу; *настукать трещину* — суккалап кайда ярык барлыгын

табу; 2. *фам.* басып ташлау (язу машинкасында); *настукать заявление* — гариза басып ташлау.

**НАСТУ'КИВАТЬ** *несов. разг.*— к. настукать.

**НАСТУПА'ТЕЛЬНЫЙ** — 1. һөҗүм...-ы, һөҗүм итү...-ы; *наступательный бой* — һөҗүм сугышы; 2. һөҗүмчән; *наступательная политика* — һөҗүмчән политика.

**НАСТУПА'ТЬ** I *несов.*— 1. басу; *наступать кому-н. на ногу* — кемнең дә булса аягына басу; 2. һөҗүм итү, алга бару; *армия успешно наступает* — армия уңышлы рәвештә алга бара.

**НАСТУПА'ТЬ** II *несов.*— к. наступить II.

**НАСТУПИ'ТЬ** I *сов.* — к. наступать I. ◇ **Наступить на ногу** *перен. разг.*— үкчәсенә басу (хәтерен калдыру, зарар китерү, зыян китерү мәгънәсендә).

**НАСТУПИ'ТЬ** II *сов.*— 1. җитү, килеп җитү; *наступила ночь* — төн җитте; 2. урнашу; *наступила тишина* — тынлык урнашты. ◇ **Наступило утро** — таң атты.

**НАСТУПЛЕ'НИЕ** I *ср.*— һөҗүм.

**НАСТУПЛЕ'НИЕ** II *ср. мн.* нет — к. наступить II.

**НАСТУ'РЦИЯ** *ж. бот.*— настурция (бакча гөле).

**НАСТУЧА'ТЬСЯ** *сов. разг.*— туйганчы шаку, туйганчы шакылдату, шакый-шакый (шакылдата-шакылдата) арып бетү.

**НАСТЫВА'ТЬ** *несов. просторец.*— к. настыть.

**НАСТЫ'НУТЬ** — к. настыть.

**НАСТЫ'ТЬ** *сов. просторец.*— 1. суыну; *комната настыла* — бүлмә суынган; 2. өшү, туңу; *я настыл, стоя на морозе* — мин салкында басып торып туңдым; 3. кату; *лёд настыл на ступеньках* — баскычларга боз каткан.

**НАСУДА'ЧИТЬ** *сов. просторец.*— гайбәт сату.

**НАСУДА'ЧИТЬСЯ** *сов. просторец.* — туйганчы гайбәт сату, гайбәт сатып тую.

**НАСУДИ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— җитәрлек судлашу, бик күп судлашу.

**НАСУЕТИ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— ыгы-зыгы килеп ару, ыгы-зыгы килеп арып бетү.

**НАСУЛИ'ТЬ** *сов. обл. просторец.* — күпне ышандыру, күп вәгъдәләр бирү.

**НАСУМАСБРО'ДИТЬ** *сов. разг. фам.*— төрле дуамаллыклар эшләп ташлау, төрле тинтәклекләр эшләп ташлау, төрле ахмаклыклар эшләп ташлау.

**НАСУ'НУТЬ** *сов. просторец.*— 1. кию, ашык-пошык кию; *насунуть сапоги* — итекне ашык-пошык кию; 2. *обл.* этеп бәрдерү; *насунуть кого-н. на косяк* — кемне дә булса этеп ишек яңагына бәрдерү.

**НАСУ'ПИТЬ** *сов.*— җыеру; *насупить брови* — кашларны җыеру.

**НАСУ'ПИТЬСЯ** *сов.* — 1. кашларны җыеру, чырай сыту; 2. *разг.* карангылану, болыт белән каплану; төмсәләнү; *небо насупилось* — күк йөзе карангыланды.

**НАСУ'ПЛИВАТЬ** *несов.*— к. насупить.

**НАСУПРОТИ'В** *нареч. обл.*— каршыда.

**НАСУРМИ'ТЬ** *сов.* — сөрмәләү, сөрмә тарту.

**НАСУРМИ'ТЬСЯ** *сов.*— сөрмә тарту.

**НАСУ'СЛИВАТЬ** *несов. просторец.*— к. насуслить.

**НАСУ'СЛИВАТЬСЯ** *несов. страд. просторец.*— төкерекләп чылатылу, төкерекләп пычратып бетерелү, төкерекләп пычратылу, селәгәйләп пычратып бетерелү.

**НАСУ'СЛИТЬ** *сов. просторец.*— төкерекләп чылату, төкерекләп пычрату, төкерекләп пычратып бетерү, селәгәйләп пычратып бетерү.

**НАСУТУ'ЛИВАТЬ** *несов.*— бөкрәйтү.

**НАСУТУ'ЛИТЬ** *сов. разг.*— к. насутуливать.

**НАСУТЯ'ЖНИЧАТЬ** *сов. просторец.*— дәгъва белән алу, дәгъвалашып алу.

**НАСУТЯ'ЖНИЧАТЬСЯ** *сов. просторец.*— туйганчы дәгъвалашу.

**НА'СУХО, СУХО-НА'СУХО** *нареч.* — коп-коры итеп, коп-коры булганчы, корытканчы.

**НАСУ'ЧИВАТЬ** *несов. спец.*— к. насучить.

**НАСУ'ЧИВАТЬСЯ** *несов. страд. спец.*— бөтереп хәзерләп куелу, катып хәзерләп куелу, чиратып хәзерләп куелу.

**НАСУЧИ'ТЬ** *сов. спец.* — (берникадәр) бөтерү, кату, чирату, бөтереп хәзерләп кую, катып хәзерләп кую, чиратып хәзерләп кую.

**НАСУ'ШИВАТЬ** *несов.*—к. насушить.

**НАСУ'ШИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— киптереп куелу, киптереп хәзерләп куелу.

**НАСУШИ'ТЬ** *сов.* — (берникадәр) киптерү, киптереп кую, киптереп хәзерләп кую.

**НАСУ'ЩНЫЙ** *книж.*— иң мөһим, бик әһәмиятле, бик кирәкле, бүгенге көн өчен әһәмиятле булган, тормыш өчен әһәмиятле булган. ◇ **Насущный хлеб** *разг.*— көндәлек ризык, яшәү өчен кирәкле ризык.

**НАСЧЁТ** *предлог с родит. п. разг.*— турында, хакында.

**НАСЧИТА'ТЬ** *сов.* — 1. санап чыгару; *насчитал около тысячи человек* — меңгә якын кеше санап чыгардым; 2. *просторец.* артык санау, артык чыгару; *насчитали на меня пять рублей* — минем өскә биш сум артык чыгарганнар.

**НАСЧИ'ТЫВАТЬ** — 1. к. насчитать; 2. саналу, исәпләнү, булу; *город насчитывает свыше двух миллионов жителей* — шәһәрдә ике миллионнан артык кеше бар.

**НАСЧИ'ТЫВАТЬСЯ** *несов. страд.*— саналу, булу; *насчитывается свыше тысячи малых планет, которые называются астероидами* — астероид дип атала торган меңнән артык кечкенә планета бар.

**НАСЫЛА'ТЬ** *несов. книж.*— к. наслать.

**НАСЫЛА'ТЬСЯ** *несов. страд. книж.*— җибәрелү.

**НА'СЫП** *м. обл. спец.*— мөшкә (тегермәндә тарттырганда игенне салу өчен хезмәт итә торган воронкасыман ящик).

**НАСЫПА'ЛЬЩИК** *м.*, **НАСЫПА'ЛЬЩИЦА** *ж. спец.*— тутыручы, салып торучы.

**НАСЫ'ПАТЬ** *сов. разг.*— 1. салу, тутыру,

салып кую, тутырып кую; *насыпать муку в ларь* — онны ларга салып кую; 2. сибү, сибеп чыгу; *насыпать песку на дорожку* — юлга ком сибеп чыгу; 4. (*возвести из сыпучих материалов*) өю; 5. *простореч. вульг. (побить кого-н.)* кирәген бирү, тукмау, дөмбәсләү.

**НАСЫПА'ТЬ** I *несов.* — к. насыпать.

**НАСЫПА'ТЬ** II *несов. простореч.* — к. наспать.

**НАСЫ'ПАТЬСЯ** *сов. разг.* — коелу, коелып төшү.

**НАСЫПА'ТЬСЯ** I *несов. разг.* — 1. к. насыпаться; 2. *страд.* салып куелу, тутырып куелу; сибеп чыгылу; өелү.

**НАСЫПА'ТЬСЯ** II *несов.* — к. наспаться.

**НАСЫ'ПКА** *ж. разг.* — 1. *только ед. (действие)* к. насыпать; 2. *обл.* мендәр сүрүе.

**НАСЫПН'ОЙ** *спец.* — өеп ясалган.

**НАСЫ'ПЩИК** *м.*, **НАСЫ'ПЩИЦА** *ж. спец.* — к. насыпальщик.

**НА'СЫПЬ** *ж.* — насыпь, өем; *железнодорожная насыпь* — тимер юл насыбе. ◇ **Уголь перевозят насыпью** — ташкүмерне та́рага (капчыкларга, ящикларга һ. б.) салмыйча ташыйлар.

**НАСЫРЕ'ТЬ** *сов. разг.* — дым тарту, аз гына дымлану.

**НАСЫ'ТИТЬ** *сов. книж.* — 1. (*накормить досыта*) туйганчы ашату; 2. тулу, туендыру; *пары насытили воздух* — һавага пар тулган; *насытить раствор* — эремәне туендыру; 3. *перен.* баету; *насытить доклад фактическим материалом* — докладны фактик материал белән баету.

**НАСЫ'ТИТЬСЯ** *сов. книж.* — 1. тую, туйганчы ашау; 2. туену, тулу; *воздух постепенно насытился вредными испарениями* — һава акрынлап зарарлы парлар белән тулды.

**НАСЫХА'ТЬ** *несов. разг.* — к. насохнуть.

**НАСЫЩА'ТЬ** *несов. книж.* — к. насытить.

**НАСЫЩА'ТЬСЯ** *несов. книж.* — 1. к. насытиться; 2. *страд.* туйганчы ашатылу; туендырылу.

**НАСЫ'ЩЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *спец. книж.* — 1. туендырылу дәрәҗәсе, куелык; *насыщенность раствора* — эремәнең туендырылу дәрәҗәсе, эремәнең куелыгы; 2. байлык, тулылык.

**НАСЫ'ЩЕННЫЙ** — 1. тулган, тутырылган; 2. *спец.* туендырылган, куе; *насыщенный раствор* — туендырылган эремә; *насыщенный пар* — куе пар; 3. *(очень содержательный)* бай, тулы, бай эчтәлекле.

**НАТА'ИВАТЬ** *несов.* — к. натаять.

**НАТА'ЛКИВАТЬ** *несов.* — 1. к. натолкнуть; 2. *простореч.* к. натолкать.

**НАТА'ЛКИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — к. натолкнуться.

**НАТА'ПЛИВАТЬ** I *несов.* — к. натопить I.

**НАТА'ПЛИВАТЬ** II *несов.* — к. натопить II.

**НАТА'ПЛИВАТЬСЯ** I *несов. страд.* — ягып жылытылу, ягып кыздырылу.

**НАТА'ПЛИВАТЬСЯ** II *несов. страд.* — (берникадәр) эретелү, эретеп алыну.

**НАТА'ПТЫВАТЬ** *несов. разг.* — к. натоптать.

**НАТА'ПТЫВАТЬСЯ** *несов. страд. разг.* — таптап пычратылу, таптап бетерелү.

**НАТА'СКА** *ж. мн.* нет, *охот.* — (аўга) өйрәтү, җәнлек ауларга өйрәтү; *натаска гончих* — ау этләрен (җәнлек ауларга) өйрәтү.

**НАТАСКА'ТЬ** *сов.* — 1. (берникадәр) ташу, ташып кую; *натаскать дров* — утын ташып кую; 2. *разг.* (берникадәр) чыгару; *мальчишка натаскал раков из воды* — малай судан кыслалар чыгарган; 3. *фам. (наворовать)* урлап җыю; 4. *охот.* җәнлек ауларга өйрәтү, ауга өйрәтү; *натаскать собаку* — этне җәнлек ауларга өйрәтү; 5. *перен. разг. фам.* өстән-өстән генә хәзерләү; *натаскать учеников к экзамену* — укучыларны өстән-өстән генә имтиханга хәзерләү.

**НАТАСКА'ТЬСЯ** *сов. разг. фам.* — 1. күп йөреп арып бетү; *натаскался по городу* — шәһәрдә күп йөреп арып беттем; 2. *(потаскать вдоволь)* туйганчы ташу (мәсәлән, утын).

**НАТА'СКИВАТЬ** *несов.* — к. натаскать, натащить.

**НАТА'СКИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — (берникадәр) ташып куелу.

**НАТАСОВА'ТЬ** *сов. разг.* — аралаштыру.

**НАТА'СЧИК** *м. охот.* — этләрне ауга өйрәтүче.

**НАТА'ЧИВАТЬ** *несов.* — к. наточить.

**НАТА'ЧИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — чарлану, үткенләндерелү, кайралу.

**НАТАЩИ'ТЬ** *сов. разг.* — 1. тартып ябыну; *натащить на себя одеяло* — юрганны тартып ябыну; 2. ташып кую; *для тюфяков натащили соломы* — көрпәләргә тутыру өчен салам ташып куйдылар.

**НАТА'ЯТЬ** *сов.* — 1. (берникадәр) эретү; *натаяли много снегу* — бик күп кар эреткәннәр; 2. (берникадәр) эрү; *натаяло много снегу в погребе* — кар базында бик күп кар эрегән.

**НАТВОРИ'ТЬ** *сов. разг.* — 1. эшләп ташлау; *натворить мерзостей* — әшәкелекләр эшләп ташлау; 2. *спец.* (берникадәр) изү, изеп кую; *натворить извести* — известь изеп кую. ◇ **Натворить теста** — камыр кую.

**НА'ТЕ** *частица разг.* — мәгез!

**НАТЁК** *м.* — 1. *разг.* агып чыккан сыекча, агып җыелган сыекча; 2. *геол.* утырма, җыелма (агым суда яки башка сыекчада булган матдәнең утырмасы, җыелмасы, мәсәлән, сталагмитлар).

**НАТЕКА'ТЬ** *несов.* — к. натечь.

**НАТЕ'ЛЬНЫЙ** — эчке; *нательная рубашка* — эчке күлмәк.

**НАТЕРЕБИ'ТЬ** *сов. спец.* — (берникадәр) йолку, йолкып хәзерләп кую; *натеребить льну* — җитен йолку.

**НАТЕРЕ'ТЬ** *сов.* — 1. сөртү; *натереть лицо вазелином* — биткә вазелин сөртү; 2. балавыз (мастика) сөртеп ялтырату;

3. суйдыру, кабарту, чиләтү, сугу, тию, басу; *хомут натёр шею лошади* — атның муенына камыт тигән; 4. кыру, кырып кую; *натереть редьки* — торма кыру.

**НАТЕРЕ'ТЬСЯ** *сов.* — сөртенү.

**НАТЕРПЕ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — бик күп... баштан кичерү, бик күп... күрү, бик күп... күреп үткәрү, бик күп... чигү; *натерпеться горя* — бик күп кайгы чигү (баштан кичерү). ◇ **Натерпеться страху** — чиктән тыш курку, бик нык курку.

**НАТЕСА'ТЬ** *сов.* — (берникадәр) юнып кую, юнып хәзерләп кую; *натесать досок* — такталар юнып хәзерләп кую.

**НАТЁСЫВАТЬ** *несов.* — к. натесать.

**НАТЁСЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — юнып куелу, юнып хәзерләп куелу.

**НАТЕ'ЧЬ** *сов.* — саркып (кереп) җыелу, агып кереп җыелу; *в лодку натекло много воды* — көймәгә бик күп су саркып (кереп) җыелган.

**НАТЕ'ШИТЬ** *сов. разг.* — туйганчы көлдерү, юату.

**НАТЕ'ШИТЬСЯ** *сов. разг.* — туйганчы көлү, туйганчы уйнау, күңел ачу, туйганчы шаяру.

**НАТИ'БРИТЬ** *сов. разг. фам.* — чәлдереп җыю, урлап җыю.

**НАТИРА'ТЬ** *несов.* — к. натереть.

**НАТИРА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. натереться; 2. *страд.* сөртелү; балавыз (мастика) сөртеп ялтыратылу.

**НА'ТИСК** *м.* — 1. һөҗүм, кысрыклау, кысу; 2. *тип.* басым (басканда наборның яки клишенең кәгазьгә туры килә торган басымы); 3. *тип.* басым эзе (наборның яки клишенең басымы зур булганда кәгазьнең икенче ягында беленеп тора торган хәреф эзләре).

**НАТИ'СКАТЬ** *сов.* — 1. *разг.* күп итеп тутыру, басып тутыру, дыңгычлап тутыру, тыгызлап тутыру; *натискать книг в чемодан* — китапларны чемоданга дыңгычлап тутыру; 2. *тип.* берничә оттиск басу.

**НАТИ'СКАТЬСЯ** *сов. разг.* — тыгызланып тулу, төялү, шыгрым тулу.

**НА'-ТКА** *частица* — 1. *простореч.* к. на III; 2. *разг.* менә сиңа кирәк булса! Менә иничек!

**НАТКА'ТЬ** *сов.* — (берникадәр) туку, тукып кую, тукып хәзерләп кую.

**НАТКНУ'ТЬ** *сов.* — чәнчеп кую, кадап кую; *наткнуть бабочку на булавку* — күбәләкне булавка белән кадап кую.

**НАТКНУ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. (*наскочить на что-н. острое*) барып кадалу, барып чәнчелү; 2. барып (килеп) бәрелү, барып (килеп) төртелү; *наткнуться в темноте на что-н.* — караңгыда берәр нәрсәгә барып бәрелү; 3. *перен. разг.* очрау, тап булу, көтмәгәндә очрау, барып чыгу; *наткнуться на неприятеля* — көтмәгәндә дошман өстенә барып чыгу; *наткнуться на препятствия* — тоткарлыкларга очрау.

**НАТОЛКА'ТЬ** *сов. простореч.* — 1. эткәлитөрткәли авырттырып бетерү; *натолкали ему бока* — эткәли-төрткәли кабыргаларын авырттырып бетергәннәр; 2. (*насовать*) тыгызлап тутырып кую.

**НАТОЛКНУ'ТЬ** *сов.* — (этеп җибәреп) китереп бәрдерү; *натолкнуть кого-н. на стенку* — кемне дә булса стенага китереп бәрдерү. ◇ **Натолкнуть на мысль** — фикер тудыру. **На грех меня натолкнул** — мине гөнаһлы итте.

**НАТОЛКНУ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — к. наткнуться 2, 3.

**НАТОЛКОВА'ТЬ** *сов. простореч.* — башка туку; *натолковали ему этот вздор* — бу юк-бар нәрсәләрне аның башына тукыганнар.

**НАТОЛКОВА'ТЬСЯ** *сов. простореч.* — туйганчы сөйләшү.

**НАТОЛКО'ВЫВАТЬ** *несов. простореч.* — к. натолковать.

**НАТОЛО'ЧЬ** *сов.* — төеп кую, төеп хәзерләп кую.

**НАТО'ПАТЬ** *сов. разг. фам.* — аяк тибү, аяк тибеп кычкырыну, аяк тибеп сүгеп ташлау.

**НАТОПИ'ТЬ** I *сов.* — ягып кыздыру, ягып җылыту; *натопить печь* — мичне ягып кыздыру; *натопить комнату* — бүлмәне ягып җылыту.

**НАТОПИ'ТЬ** II *сов.* — 1. (берникадәр) эретеп алу; *натопить воску* — балавыз эретеп алу; 2. күп итеп кайнату, күп итеп кайнатып кую; *натопить молока* — күп итеп сөт кайнатып кую.

**НАТОПТА'ТЬ** *сов. разг.* — таптап пычратып бетерү, таптап эзләр калдыру (мәсәлән, идәнне).

**НАТОРГОВА'ТЬ** *сов.* — 1. (*приобрести торговлей в каком-н. колич.*) сәүдә итеп (берникадәр) акча табу; 2. ... сумлык сату; *они наторговали овощей на тысячу рублей* — алар мең сумлык яшелчә сатканнар.

**НАТОРГО'ВЫВАТЬ** *несов.* — к. наторговать.

**НАТОРЕ'ЛЫЙ** *простореч. устар.* — остарган, шомарган.

**НАТОРЕ'ТЬ** *сов. устар.* — остару, шомару, өйрәнү, күнегү.

**НАТО'РКАТЬ** *сов. обл.* — к. натыкать.

**НАТОЧИ'ТЬ** *сов.* — чарлау, үткенләү, кайрау.

**НАТОЩА'К** *нареч. разг.* — ач карынга, ач килеш; *принимать лекарство натощак* — даруны ач карынга эчү.

**НАТР** *м. мн.* нет — натр (натрий окисе). ◇ **Едкий натр** *хим. тех.* — зәһәр натр.

**НАТРАВИ'ТЬ** I *сов.* — 1. өстерү, куу (эт белән); *натравить собак на зайца* — этләрне куянга өстерү; 2. *перен. разг.* котырту; *натравили на него соседа* — аңа каршы күршесен котыртканнар; 3. (берникадәр) агулап бетерү, агулап үтереп бетерү, кырып бетерү; *натравить тараканов* — тараканнарны агулап үтереп бетерү; 4. таптап бетерү; *скот натравил много посевов* — терлек бик күп чәчүлекне таптап бетергән.

**НАТРАВИ'ТЬ** II *сов. спец.* — рәсемнәр (бизәкләр) төшерү (кислота белән ашатып ме-

таллга рәсемнәр төшерү турында); *натравить узор на крышке* — капкачка яндырып бизәк төшерү.

**НАТРА'ВЛИВАТЬ** I *несов.* — к. натравить I.

**НАТРА'ВЛИВАТЬ** II *несов.* — к. натравить II.

**НАТРА'ВЛИВАТЬСЯ** I *несов. страд.* — 1. өстерелү; 2. котыртылу; 3. агулап үтереп бетерелү; 4. таптап бетерелү.

**НАТРА'ВЛИВАТЬСЯ** II *несов. страд.* — (кислота белән ашатып) төшерелү (рәсемнәр, бизәкләр турында).

**НАТРАВЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. натравливать I, II.

**НАТРАВЛЯ'ТЬСЯ** *несов.* — к. натравливаться I, II.

**НАТРА'ВЩИК** *м. спец.* — натравщик (кислота һ. б. белән ашатып бизәк, рәсем төшерүче эшче).

**НАТРА'ТИТЬ** *сов. разг.* — (берникадәр) тоту, туздыру, тотып бетерү; *натратить денег* — акча тоту.

**НАТРЕ'БОВАТЬ** *сов. разг.* — (берникадәр) таләп итү.

**НАТРЕНИРОВА'ТЬ** *сов. спорт.* — күнектереп җиткерү.

**НАТРЕНИРОВА'ТЬСЯ** *сов. спорт.* — күнегеп җитү.

**НАТРЕ'НЬКИВАТЬ** *несов. фам.* — чирткәләү, чирткәләп утыру (музыка коралында); *натренькивать на балалайке* — балалайка чирткәләп утыру.

**НАТРЕПА'ТЬ** *сов. простореч.* — 1. *спец.* (берникадәр) талку, талкып кую, талкып хәзерләп кую; *натрепать льну* — житен талкып кую; 2. (берникадәр) язу, язып хәзерләп кую, тетеп кую, тетеп хәзерләп кую; *натрепать шерсти* — йон тетеп кую; 3. *перен. простореч.* юк-барны сөйләп ташлау, ялганлау.

**НАТРЕ'СКАТЬСЯ** *сов. вульг.* — 1. гарык булганчы ашау, тыгыну; 2. лаякыл исерү.

**НАТРЕ'СНУТЬ** *сов. разг. устар.* — бераз чатнау; *стакан натреснул* — стакан бераз чатнаган.

**НАТРЕЩА'ТЬ** *сов. простореч.* — 1. (*много потрещать*) озак шатырдап тору; (*о кузнечиках*) озак череллдәп тору; 2. *преимущ. неодобр.* бик күп (озак) такылдау, бик күп (озак) лыгырдау, бик күп (озак) юк-барны сөйләү.

**НА'ТРИЙ** *м. мн.* нет, *хим.* — натрий (химик элемент; йомшак һәм җиңел металл).

**НА'ТРОЕ** *нареч.* — өчкә, өч кисәккә, өч өлешкә.

**НАТРУБИ'ТЬ** *сов. разг.* — озак итеп быргы кычкырту. ◇ Натрубить в уши *разг. неодобр.* — колакка туку.

**НАТРУДИ'ТЬ** *сов. разг.* — авыр китерү, ялыктыру, талчыктыру; *натрудил себе руку* — кулыма авыр китердем (озак эшләп яки авыр эш эшләп).

**НАТРУДИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. авыр килү; ялыгу, талчыгу; *рука натрудилась* — кулыма авыр килде (озак эшләүдән яки авыр эш эшләүдән); 2. (*потрудиться вдоволь*) туйганчы эшләү, җитәрлек эшләү.

**НАТРУ'ЖИВАТЬ** *несов. разг.* — к. натрудить.

**НАТРУСИ'ТЬ** *сов. обл. спец.* — селкеп кою, селкеп төшерү, кагып төшерү.

**НАТРУСИ'ТЬСЯ** *сов. обл. спец.* — селкенеп коелу.

**НАТРЯСА'ТЬ** *несов. разг.* — к. натрясти.

**НАТРЯСТИ'** *сов.* — селкеп төшерү, селкеп кою.

**НАТРЯСТИ'СЬ** *сов. разг.* — 1. озак калтырау; *натряcся от страха* — куркудан озак калтырадым; 2. бик нык селкетү; *натряслась в телеге* — арбада мине бик нык селкетте; 3. селкенеп коелу; *натряслось много крошек* — селкенеп бик күп валчык коелган.

**НАТУ'ГА** *ж. мн.* нет: с натуги — көчәнүдән; от натуги — тартудан, тартылудан; *ремень лопнул от натуги* — каеш тартудан (тартылудан) өзелде.

**НА'ТУГО, ТУГО-НА'ТУГО** *нареч. разг.* — бик нык кысып, бик нык тартып.

**НАТУ'ЖИВАТЬ** *несов. разг.* — к. натужить.

**НАТУ'ЖИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — к. натужиться.

**НАТУ'ЖИТЬ** *сов. разг.* — киерү; *натужить мускул* — мускулны киерү.

**НАТУ'ЖИТЬСЯ** *сов. разг.* — көчәнү, киерелү.

**НАТУЖИ'ТЬСЯ** *сов. простореч.* — күп кайгыру, күп кайгы-хәсрәт чигү.

**НАТУ'ЖНЫЙ** *разг.* — 1. көчәнеп эшләнә торган, авыр эшләнә торган; 2. *перен.* ясалма, көчәнүле; *натужное веселье* — ясалма шатлану, ясалма күңеллелек.

**НАТУ'РА** *ж.* — 1. *только ед. устар.* (*природа*) табигать; 2. (*темперамент, характер*) табигать, холык, характер; 3. *спец.* натура; 4. *только ед. торг. экон.* натура; *платить натурой* — натуралата түләү. ◇ В натуре *разг. шутл.* — ялангач, шәрә, киемсез.

**НАТУРАЛИЗА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *право полит.* — натурализация (берәр дәүләтнең чит ил кешесенә гражданлык хокукы бирүе яки берәр кешенең чит дәүләт гражданлыгына күчүе).

**НАТУРАЛИ'ЗМ** *м. мн.* нет — натурализм (1. *филос. вульг.* материализмга якын булган һәм иҗтимагый күренешләрне табигать факторлары белән генә аңлата торган философик юнәлеш; 2. *лит. искус.* әдәбиятта һәм сәнгатьтә реализмга капма-каршы булган, объектив рәвештә диган булып, чынбарлыкның нәкъ фотографик копиясен бирергә омтыла торган юнәлеш).

**НАТУРАЛИЗОВА'ТЬ** *сов.* и *несов. право полит.* — чит ил кешесенә гражданлык хокукы бирү.

**НАТУРАЛИЗОВА'ТЬСЯ** *сов.* и *несов. право полит.* — чит дәүләт гражданлыгын кабул итү.

**НАТУРАЛИ'СТ** *м. книж.* — 1. натуралист; *юный натуралист* — яшь натуралист; 2. (*последователь натурализма*) натурализм тарафдары, натуралист.

**НАТУРА'ЛЬНО** — 1. *нареч.* табигый, та-

бигый рәвештә; 2. *в знач. ввод. сл. устар.* билгеле, шиксез, әлбәттә, табигый.

**НАТУРА'ЛЬНЫЙ** *книж.* — 1. табигый, чын (ясалма түгел); в *натуральную величину* — табигый зурлыкта; *натуральный шёлк* — чын ефәк; 2. натуралата түләнә торган, натураль (акчалата түгел); *натуральный налог* — натуралата түләнә торган налог. ◇ Натуральный ряд чисел *мат.* — саннарның натураль рәте (саннарның эзлекле рәвештә төзелеше, мәсәлән, 1, 2, 3 һ. б.). Натуральная школа *лит.* — натураль мәктәп (XIX йөзнең 30—40 елларында рус әдәбиятында булган реалистик агым).

**НАТУ'РНЫЙ** — 1. *живоп.* натурадан төшерү...-ы; *натурный класс* — натурадан төшерү классы; 2. *кино* табигый шартларда төшерелгән; *натурные съёмки* — табигый шартларда төшерелгән съёмкалар; 3. *экон. торг.* товар...-ы, продукт...-ы, товарлата...; *натурный остаток* — товар калдыгы; *натурная оплата* — товарлата түләү.

**НАТУРФИЛО'СОФ** *м. филос.* — натурфилософ, натурфилософия тарафдары.

**НАТУРФИЛОСО'ФИЯ** *ж. мн.* нет, *филос.* — натурфилософия (философиянең абстракт принципларына нигезләп, табигать турында тулы мәгълүматлар бирергә тырышучы идеалистик тәгълимат. Бу тәгълиматның үсеше бигрәк тә XVI — XVIII гасырларга туры килә).

**НАТУ'РЩИК** *м.* — натурщик (сурәт яки сын ясаучыга күчергеч булып торучы ир кеше).

**НАТУ'РЩИЦА** *ж.* — натурщица (сурәт яки сын ясаучыга күчергеч булып торучы хатын-кыз).

**НАТЫ'КАТЬ** *сов. разг.* — 1. күп итеп кадап кую; *натыкать иголок в подушечку* — энә капчыгына энәләр кадап кую; 2. чәнечкәләп чыгу, чәнчеп чыгу; *натыкать яблоки перед варкой* — варенье кайнату алдыннан алмаларны чәнчеп чыгу.

**НАТЫКА'ТЬ** *несов. разг.* — 1. к. натыкать; 2. к. наткнуть.

**НАТЫКА'ТЬСЯ** *несов.* — к. наткнуться.

**НАТЮРМО'РТ** *м. живоп.* — натюрморт (1. *только ед.* җимеш, чәчәк, балык, атып төшерелгән кош һ. б. җансыз әйберләрне рәсемгә төшерү; 2. шундый рәсемнең үзе).

**НАТЯГА'ТЬ** *сов. просторeч.* — суырып җыю, суырып чыгарып җыю, тартып чыгарып җыю; *натягать гвоздей из доски* — тактадан кадаклар суырып чыгарып җыю.

**НАТЯ'ГИВАТЬ** *несов.* — к. натянуть.

**НАТЯ'ГИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. натянуться; 2. *страд.* киерелү, тартылу.

**НАТЯЖЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — 1. к. натянуть, натягиваться; 2. *мед.* (*о ране*) каплану, тартылу, бөтәшү.

**НАТЯ'ЖКА** *ж. разг.* — 1. *только ед.* к. натяжение 1; 2. тарткалау-сузгалау, тартусузу; *с натяжкой это можно допустить* — тарткалап-сузгалап моны шулай дип уйларга мөмкин.

**НАТЯ'НУТОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — 1. к. натягиваться; 2. *перен.* ясалмалык; 3. *перен.* киеренкелек.

**НАТЯ'НУТЫЙ** — 1. киерелгән, тартылган; 2. *перен.* ясалма; *сцена эта может показаться очень натянутой* — бу сценаның бик ясалма булып күренүе мөмкин; 3. *перен.* киеренке, тартынкы; *натянутые отношения* — киеренке мөнәсәбәтләр.

**НАТЯНУ'ТЬ** *сов.* — 1. киерү, тарту, сузу; *натянуть тетиву лука* — җәянең керешен киерү; *натянуть струны на скрипку* — скрипкага кыл тарту; 2. *разг.* кию, тартып кию; *натянуть сапог* — күн итекне тартып кию; 3. тартып ябыну, ябыну; *натянуть на себя одеяло* — юрганны тартып ябыну.

**НАТЯНУ'ТЬСЯ** *сов.* — тартылу, киерелү.

**НАУГА'Д** *нареч. разг.* — ни булса ул булыр дип, тәвәккәлләп, уйлап-нитеп тормыйча.

**НАУГО'ЛЬНИК** *м. спец.* — почмаклык (1. почмак сызу коралы; 2. тәрәзә рамы, ящик һ. б. почмагына бизәү яки беркетү өчен куела торган нәрсә; 3. почмакка куела торган өчпочмаклы киштә).

**НАУГО'ЛЬНЫЙ** *спец.* — почмакка куела торган.

**НАУДАЛУ'Ю** *нареч. разг.* — 1. дуамал кыюлык белән; *ринуться наудалую* — дуамал кыюлык белән ташлану; 2. к. наудачу.

**НАУДА'ЧУ** *нареч.* — тәвәккәлләп, ни булса ул булыр дип, уңса уңар дип, уйлапнитеп тормыйча; *идти наудачу* — ни булса ул булыр дип бару.

**НАУДИ'ТЬ** *сов.* — кармак белән (берникадәр) тоту, кармак белән тотып алу; *наудить карасей* — кармак белән (берникадәр) табан балыгы тоту.

**НАУЗНАВА'ТЬ** *несов. разг.* — к. наузнать.

**НАУЗНА'ТЬ** *сов. разг.* — күпне белү; *чего только не наузнал я там* — мин анда нәрсәләр генә белмәдем.

**НАУ'КА** *м.* — 1. фән, гыйлем; 2. *только ед.* сабак, гыйбрәт. ◇ Отдать в науку *просторeч.* — укырга бирү, укыту.

**НАУКООБРА'ЗНЫЙ** *книж.* — фәнсыман, фәнгә охшаган (тыштан карaганда гына фәнни булган, чынында исә фәнни булмаган).

**НАУСТИ'ТЕЛЬ** *м. устар. теперь ирон.* — котыртучы, өстерүче, коткы башы, коткы салучы.

**НАУСТИ'ТЬ** *сов. устар.* — к. наущать.

**НАУ'СЬКАТЬ** *сов. просторeч.* — котыртып җибәрү, өстереп җибәрү.

**НАУ'СЬКИВАТЬ** *несов. просторeч.* — к. науськать.

**НАУТЁК** *нареч. разг. фам.*: пуститься наутёк — сызу, таю, шылу, табан ялтырату (качып китү).

**НАУ'ТРО** *нареч.* — иртә белән, иртәгесен, иртәгә иртән, иртәгә иртә белән, икенче көнне иртә белән.

**НАУЧА'ТЬ** *несов. устар.* — к. научить.

**НАУЧА'ТЬСЯ** *несов. устар.* — к. научиться.

**НАУ'ЧЕННЫЙ** — өйрәтелгән.

**НАУЧИ'ТЬ** *сов.* — өйрәтү; *научить ремеслу* — һөнәргә өйрәтү.

**НАУЧИ'ТЬСЯ** *сов.* — өйрәнү.

**НАУ'ЧНО-ИССЛЕ'ДОВАТЕЛЬСКИЙ** *книж.* — фәнни-тикшеренү...-ы; *научно-исследовательский институт* — фәнни-тикшеренү институты.

**НАУ'ЧНЫЙ** — фәнни, гыйльми; *научная работа* — фәнни эш. ◇ С научной точки зрения — фән ноктасыннан караганда, фәнни күзлектән караганда.

**НАУ'ШНИК** *м.* — 1. (*часть тёплой шапки*) колакчын; 2. наушник (радиода, телефонда); 3. *разг. презрит.* әләкче, гайбәтче, гайбәт капчыгы, астыртын яла ягучы, сүз йөртүче.

**НАУ'ШНИЦА** *ж. презрит*—к. наушник 3.

**НАУ'ШНИЧАТЬ** *несов. разг. презрит.*— астыртын әләкләү, астыртын гайбәт сату, яла ягу, сүз йөртү.

**НАУ'ШНИЧЕСТВО** *ср. мн.* нет, *разг. презрит.* — астыртын сүз йөртү, яла ягу, астыртын әләкләү, астыртын гайбәт сөйләү.

**НАУЩА'ТЬ** *несов., устар.* — котырту, астыртын котырту, начарлыкка өйрәтү.

**НАФАБРИКОВА'ТЬ** *сов. разг. неодобр.*: нафабриковать ложные слухи — ялган хәбәрләр уйлап чыгару; нафабриковать фальшивки — ялган документлар бастырып чыгару, ялган документлар тарату.

**НАФА'БРИТЬ** *сов. устар.* — фабра сөрү (сакал-мыекка).

**НАФА'БРИТЬСЯ** *сов. устар.* — фабра сөртенү.

**НАФТАЛИ'Н** *м.* — нафталин.

**НАХА'ЖИВАТЬ** *несов. просторечь.* — кирәгеп бирү, яру („кыйнау“ мәгънәсендә); *нахаживать плёткой* — камчы белән яру.

**НАХА'Л** *м.* — нахал, оятсыз, битсез, җир бит.

**НАХА'ЛЬНИЧАТЬ** *несов. разг.* — оятсызлану, оятсыз рәвештә бәйләнү.

**НАХА'ЛЬНЫЙ** — оятсыз; *нахальный человек* — оятсыз кеше.

**НАХА'ЛЬСТВО** *ср. мн.* нет — оятсызлык, нахаллык.

**НАХА'ПАТЬ** *сов. просторечь. вульг.* — урлап җыю, комсызланып җыю.

**НАХА'РКАТЬ** *сов. просторечь.* — какырып пычратып бетерү.

**НАХВА'ЛИВАТЬ** *несов. разг* — к. нахвалить.

**НАХВАЛИ'ТЬ** *сов. разг.* — бик нык мактау; кирәгеннән артык мактау, күтәрү; *нахвалили мне его, а работник-то он плохой* — аны миңа бик нык мактадылар, ә ул начар работник булып чыкты.

**НАХВАЛИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. мактану, бик күп мактану; *ещё успеешь нахвалиться* — мактанырга өлгерерсең әле; 2. *с отриц.* мактап бетерә алмау; *мать не могла нахвалиться сыном* — әнисе улын мактап бетерә алмый иде.

**НАХВА'СТАТЬ** *сов. разг.*— бик күп мактану, шапырыну.

**НАХВА'СТАТЬСЯ** *сов. разг.* — к. нахвастать.

**НАХВАТА'ТЬ** *сов. разг.* — 1. (берникадәр) тоту, тотып алу; *нахватать руками рыб* — кул белән (берникадәр) балык тотып алу; 2. (*набрать, приобрести в каком-н. колич.*) җыю (берникадәр); 3. к. нахвататься.

**НАХВАТА'ТЬСЯ** *сов. разг. неодобр.*: нахвататься знаний — аннан-моннан гына белем алу; нахвататься сведений — аннан-моннан гына мәгълүматлар җыю; нахвататься всякой чепухи — җыен юк-барны башка тутыру.

**НАХЛЕБА'ТЬСЯ** *сов. просторечь.*— туйганчы ашау, ашап тую (аш, щи турында).

**НАХЛЕ'БНИК** *м. устар.*— 1. нахлебник (аш һәм торак өчен акча түләп квартирада торучы); 2. *неодобр.* (*бездельник*) эрәм тамак, тик торып ашап ятучы, эшләмичә ашаучы, кеше җилкәсен кимерүче.

**НАХЛЕ'БНИЧАТЬ** *несов. устар.*— кеше җилкәсен кимереп яту.

**НАХЛЕСНУ'ТЬ** *сов.* — әләктереп кую (бауны); әләктереп алу (элмәкле бау белән).

**НАХЛЕСТА'ТЬ** *сов. разг.* — камчылау, чыбыклау, кыйнау, суктыру.

**НАХЛЁСТА'ТЬСЯ** *сов. просторечь.* — туйганчы чабыну, чабынып тую; *нахлестаться в бане* — мунчада туйганчы чабыну.

**НАХЛЕСТНУ'ТЬ** *сов.* — к. нахлеснуть.

**НАХЛЁСТЫВАТЬ** I *несов.*— к. нахлестать.

**НАХЛЁСТЫВАТЬ** II *несов.*— к. нахлеснуть.

**НАХЛЁСТЫВАТЬСЯ** *несов. просторечь.*— к. нахлестаться.

**НАХЛОБУ'ЧИВАТЬ** *несов. разг.*— к. нахлобучить.

**НАХЛОБУ'ЧИВАТЬСЯ** *несов. страд. разг.*— басып киелү, батырып киелү.

**НАХЛОБУ'ЧИТЬ** *сов.*— 1. басып кию, батырып кию; *нахлобучить шапку* — бүрекне басып кию; 2. *фам.* кирәгеп бирү (орышу яки кыйнау мәгънәсендә).

**НАХЛОБУ'ЧКА** *ж.*— 1. *разг. фам.* каты шелтә, тиргәү; *получить нахлобучку* — каты шелтә алу; 2. *устар.* (*удар по голове*) башка сугу.

**НАХЛО'ПАТЬ** *сов. разг.*— 1. шапылдата-шапылдата авырттырып (кабартып, шештереп) бетерү; 2. *фам.* чәбәкләү; *нахлопать кому-н. спину* — кемнең дә булса аркасын чәбәкләү.

**НАХЛО'ПАТЬСЯ** *сов. разг.*— туйганчы кул чабу.

**НАХЛО'ПНУТЬ** *сов. обл.*— шап иттереп ябып кую, шап иттереп каплап кую; *нахлопнуть котёл* — казанны шап иттереп ябып кую.

**НАХЛОПОТА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — берәр эш артыннан йөри-йөри арып бету.

**НАХЛО'ПЫВАТЬ** *несов. разг. обл.*— к. нахлопать, нахлопнуть.

**НАХЛЫ'НУТЬ** *сов.*— 1. ыргылып килеп бәрелү, ишерелеп килеп менү; *волны нахлынули на берег* — дулкыннар ыргылып килеп ярга бәрелделәр; 2. *перен.* ябырылу, ябырылып килеп тулу, ябырылып ташлану, ыргылу; *молодёжь к нему нахлынула* — яшьләр аңа ябырылды; *толпа нахлынула*

*на площадь* — халык төркеме мәйданга ургылды. ◇ Нахлынули разные мысли — башыма төрле фикерләр тулды.

**НАХМУ'РИВАТЬ** *несов.* — каш җыеру, чырай сыту.

**НАХМУ'РИВАТЬСЯ** *несов.* — каш җыеру, чырай сыту, чырае сытылу, чырае караңгылану, төмсәләнү.

**НАХМУ'РИТЬ** *сов.* — к. нахмуривать.

**НАХМУ'РИТЬСЯ** *сов.* — к. нахмуриваться.

**НАХОДИ'ТЬ** I *несов.* — к. найти I.

**НАХОДИ'ТЬ** II *несов.* — к. найти II.

**НАХОДИ'ТЬСЯ** I *несов.* — к. найтись. ◇ **В то время я находился в Крыму** — ул вакытта мин Кырымда идем. **Он находится сейчас в Крыму** — ул хәзер Кырымда. **Он находился в хорошем настроении** — аның кәефе яхшы иде. **Он находится в хорошем настроении** — аның кәефе яхшы.

**НАХОДИ'ТЬСЯ** II *сов. разг. фам.* — арыганчы йөрү, йөреп ару, туйганчы йөрү, йөреп тую.

**НАХО'ДКА** *ж.* — **1.** табылдык, табылган нәрсә; **2.** *перен. разг.* табыш.

**НАХО'ДЧИВОСТЬ** *ж. мн.* нет — тапкырлык.

**НАХО'ДЧИВЫЙ** — тапкыр.

**НАХОЛА'ЖИВАТЬ** *несов. простореч.* — к. нахолодить.

**НАХОЛА'ЖИВАТЬСЯ** *несов. страд. простореч.* — суытылу.

**НАХОЛОДИ'ТЬ** *сов. простореч.* — суыту, суытып бетерү (мәсәлән, өйгә суык кертеп).

**НАХО'ХЛИВАТЬ** *несов.* — к. нахохлить.

**НАХО'ХЛИВАТЬСЯ** *несов.* — к. нахохлиться.

**НАХО'ХЛИТЬ** *сов.* — тырпайту, кабарту.

**НАХО'ХЛИТЬСЯ** *сов.* — **1.** (*о птицах*) кабарыну, йон кабарту; **2.** *перен. разг. фам.* чырай бозу, чырай сыту, төмсәләнү; *что это ты нахохлился?* — нәрсә син болай чыраеңны сыттың?

**НАХОХОТА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — туйганчы шаркылдап көлү, көлеп эч катып бетү.

**НАХРА'ПИСТЫЙ** *простореч.* — оятсыз.

**НАХРА'ПОМ** *нареч. простореч.* — көтмәгәндә, оятсыз рәвештә, көчләп.

**НАЦАРА'ПАТЬ** *сов.* — **1.** (*сделать царапины*) тырнап эз калдыру; **2.** *разг.* (*написать неразборчиво, неумело*) сызгалап ташлау, начар гына итеп язып ташлау.

**НАЦЕДИ'ТЬ** *сов.* — агызып алу, сөзеп алу, саркытып алу.

**НАЦЕДИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — агу, сарку.

**НАЦЕ'ЖИВАТЬ** *несов.* — к. нацедить.

**НАЦЕ'ЖИВАТЬСЯ** *несов.* — **1.** *разг.* к. нацедиться; **2.** *страд.* сөзелү, сөзеп алыну, агызып алыну, саркытып алыну.

**НАЦЕ'ЛИВАТЬ** *несов.* — к. нацелить.

**НАЦЕ'ЛИВАТЬСЯ** *несов.* — **1.** к. нацелиться; **2.** *страд.* төбәлү; юнәлдерелү.

**НАЦЕ'ЛИТЬ** *сов.* — **1.** төзәү, төбәү; *нацелить ружьё* — мылтык төзәү; **2.** *перен.* юнәлдерү, юнәлтү; юнәлеш бирү; *правильно нацелить наступление* — һөҗүмгә дөрес юнәлеш бирү; **3.** *простореч.* к. нацелиться.

**НАЦЕ'ЛИТЬСЯ** *сов.* — **1.** (*при стрельбе, бросании*) төзәү, төбәү; **2.** *перен. разг. фам.* (*приготовиться взять, схватить*) алырга хәзерләнү, алырга хәзерләнеп тору; **3.** *перен. разг.* (берәр фикергә) бирелү; **4.** *разг. фам.* җыену, барырга җыену.

**НА'ЦЕЛО** *нареч. разг.* — калдыксыз, тулысынча; *число делится нацело* — сан калдыксыз бүленә.

**НАЦЕЛОВА'ТЬСЯ** *сов.* — туйганчы үбешү.

**НАЦЕ'НИВАТЬ** *несов. торг.* — к. наценить.

**НАЦЕ'НИВАТЬСЯ** *несов. страд. торг.* — хак арттырылу, хак өстәлү.

**НАЦЕНИ'ТЬ** *сов. торг.* — хак арттыру, хак өстәү.

**НАЦЕ'НКА** *ж. торг.* — **1.** *только ед.* (*действие*) к. наценить; **2.** өстәмә хак, өстәлгән хак.

**НАЦЕПИ'ТЬ** *сов.* — эләктерү, эләктереп кую; элү, элеп кую; тагу, тагып кую, кадау, кадап кую; *нацепить вёдра на коромысло* — чиләкләрне көянтәгә тагу; *нацепить бант* — бант кадап кую.

**НАЦЕПЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. нацепить.

**НАЦЕПЛЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — элеп куелу, тагып куелу, кадап куелу, эләктереп куелу.

**НАЦИОНА'Л-СОЦИАЛИ'СТЫ** *мн.* — милләтче социалистлар (гитлерчы фашистлар партиясе, Бөек Ватан сугышында Совет армиясе тарафыннан тар-мар ителде).

**НАЦИОНАЛИЗА'ЦИЯ** *ж. полит.* — национализация (**1.** хосусый милекне дәүләт милкенә әверелдерү; **2.** милли республикаларда һәм өлкәләрдә формасы ягыннан милли, эчтәлеге ягыннан социалистик булган иҗтимагый учреждениеләр оештыру).

**НАЦИОНАЛИЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. полит.* — национализацияләү, национализация ясау, национализировать итү.

**НАЦИОНАЛИЗИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. полит.* — **1.** милли характер алу, милли характерда булу; **2.** *страд.* национализация ясалу, национализировать ителү.

**НАЦИОНАЛИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *полит.* — милләтчелек.

**НАЦИОНАЛИЗОВА'ТЬ** *сов.* и *несов. полит.* — к. национализировать.

**НАЦИОНАЛИЗОВА'ТЬСЯ** *сов.* и *несов. полит.* — к. национализироваться.

**НАЦИОНАЛИ'СТ** *м. полит.* — милләтче (**1.** милләтчеләр тарафдары; милләтчеләр партиясе члены; **2.** милли хәрәкәткә катнашучы).

**НАЦИОНАЛИСТИ'ЧЕСКИЙ** — милләтчелек...-ы; милләтчеләр...-ы; *националистическая политика* — милләтчелек политикасы; *националистическое движение* — милләтчеләр хәрәкәте.

**НАЦИОНАЛИСТИ'ЧНЫЙ** *книж.* — милләтчелек...-ы; *националистичные взгляды* — милләтчелек карашлары.

**НАЦИОНАЛИ'СТКА** *полит.* — к. националист.

**НАЦИОНА'ЛЬНОСТЬ** *ж.*— милләт; *Совет Национальностей* — Милләтләр Советы.

**НАЦИОНА'ЛЬНЫЙ** — 1. милли; *национальная политика* — милли политика; *местное национальное население* — җирле милли халык. ◇ **Национальное меньшинство (нацменьшинство)** *полит.*— азчылык милләт.

**НА'ЦИЯ** *ж.* — милләт. ◇ **Организация Объединенных наций** — Берләшкән милләтләр оешмасы.

**НАЦМЕ'Н** *м.*, **НАЦМЕ'НКА** *ж.*— азчылык милләт кешесе.

**НАЦМЕНЬШИНСТВО'** *ср.* — азчылык милләт.

**НАЧАДИ'ТЬ** *сов.*— сөремләп бетерү, сөрем чыгару, сөрем белән тутыру.

**НАЧА'ЛО** *ср.*— 1. баш, башлану; *в начале года* — ел башында; *начало спектакля в 8 часов* — спектакль сәгать сигездә башлана; 2. *книж. устар.* баш, баш сәбәп; *праздность — начало всех зол* — эшсезлек (эшләми тик яту) — барлык явызлыкның да башы (баш сәбәбе) ул; 3. *только ед. книж.* нигез, башлангыч; *основное начало* — төп нигез, төп башлангыч; 4. *только мн. книж.* төп положениеләр, нигезләр, принциплар; *начала физики* — физиканың төп положениеләре; 5. закон, кагыйдә; *первое начало Ньютона* — Ньютонның беренче законы. ◇ **Брать начало** — башлану, башланып китү. **Положить** *чему-н.* **начало** — (берәр нәрсәне) башлап җибәрү, (берәр нәрсәгә) нигез салу, нигез булып китү. **Давать** *чему-н.* **начало** — (берәр нәрсәгә) нигез булу, (берәр нәрсәгә) нигез булып тору. **По началу** *разг.*— башта, баштан. **Под началом** *устар.*— кул астында. **Под начало, под начал** *устар.* — кул астына, җитәкчелегенә. **Лиха беда начало** — башлап җибәрүе генә кыен. **На коллективных началах** — коллектив белән эшләү нигезендә. **Работа на новых началах** — яңа нигезләргә корылган эш.

**НАЧА'ЛЬНИК** *м.*, **НАЧА'ЛЬНИЦА** *ж.*— начальник, башлык, түрә.

**НАЧА'ЛЬНИЧЕСКИЙ** *устар.*— 1. начальник...-ы; башлык...-ы; начальниклар...-ы; башлыклар...-ы; *начальнические обязанности* — начальник вазифалары; 2. *неодобр.* к. начальственный.

**НАЧА'ЛЬНЫЙ** — 1. башлангыч; *начальная скорость* — башлангыч тизлек; *начальная школа* — башлангыч мәктәп; *начальные основания арифметики* — арифметиканың башлангыч нигезләре; 2. *простореч.* башлык итеп куелган, начальник итеп куелган; *начальные люди* — башлык итеп куелган кешеләр.

**НАЧА'ЛЬСТВЕННЫЙ** *книж.*— 1. начальник...-ы, башлык...-ы, начальниклар...-ы, башлыклар...-ы; 2. *перен.* башлыкларга хас; *начальственный тон* — башлыкларга хас тон.

**НАЧА'ЛЬСТВО** *ср. мн.* нет — 1. *собир.* начальниклар, башлыклар, эш башында торучылар; 2. *разг.* начальник, башлык; *он был моим начальством* — ул минем начальнигым (башлыгым) иде; *это случилось в его начальство* — бу вакыйга ул начальник (башлык) чакта булган иде. ◇ **Принять начальство** — җитәкчелекне кабул итү, начальник (башлык) булып эшли башлау.

**НАЧА'ЛЬСТВОВАТЬ** *несов. книж. устар.*— начальник булып тору, начальник булып эшләү, башлык булып тору, башта тору, җитәкчелек итү.

**НАЧА'ТКИ** *ед.* нет — башлангыч мәгълүматлар, элементар мәгълүматлар; *начатки арифметики* — арифметикадан башлангыч мәгълүматлар. ◇ **Начатки знаний** — башлангыч белемнәр, элементар белемнәр.

**НАЧА'ТЬ** *сов.*— башлау, керешү; *отец начал стареть* — әтием картая башлады; *начать работать* — эшли башлау, эшкә керешү. ◇ **Начать своё** *разг.*— үзенекен итә башлау. **Начать с того, что...** *разг.*— башта шуны әйтергә кирәк..., иң элек шуны әйтергә кирәк...

**НАЧА'ТЬСЯ** *сов.*— башлану, башланып китү.

**НАЧЕКА'НИВАТЬ** *несов. спец.*— к. начеканить.

**НАЧЕКА'НИВАТЬСЯ** *несов. страд. спец.*— (акча) сугылу, (акча) сугып хәзерләнү.

**НАЧЕКА'НИТЬ** *сов. спец.*— (акча) сугу, (акча) сугып хәзерләү.

**НАЧЕКУ'** *нареч.*— әзер, сак; *быть начеку* — әзер тору, сак булу.

**НАЧЁРКАТЬ, НАЧЕРКА'ТЬ** *сов. разг.*— сызгалап бетерү, сызгалап пычратып бетерү.

**НАЧЕРНИ'ТЬ** *сов.*— 1. каралту, карага буяу, кара төскә кертү; 2. (*сделать слишком чёрным*) артык каралту, кирәгеннән тыш каралту.

**НА'ЧЕРНО, НАЧЕРНО'** *нареч.*— карага, каралама итеп (язу).

**НАЧЕ'РПАТЬ** *сов.*— чумырып алу, чумырып алып тутыру, сосып тутыру, сосып алу.

**НАЧЕ'РПЫВАТЬ** *несов.*— к. начерпать.

**НАЧЕ'РПЫВАТЬСЯ** *несов. страд.*— чумырып алыну, чумырып алып тутырылу, сосып тутырылу, сосып алыну.

**НАЧЕРТА'НИЕ** *ср. книж.*— 1. язылу, язылыш; *начертание буквы* — хәрефнең язылышы; 2. *устар.* кулланма; *краткое начертание геометрии* — геометриядән кыскача кулланма.

**НАЧЕРТА'ТЬ** *сов. книж. устар.* — 1. (*написать*) язу, язып кую; 2. (*нарисовать*) төшерү, төшереп кую (сурәт, сын); 3. (*предсказать, определить*) алдан әйтеп кую, алдан билгеләп кую.

**НАЧЕРТИ'ТЬ** *сов.*— 1. сызу, төшерү; *начертить карту Австралии* — Австралия картасын сызу; *начертить план* — план төшерү; 2. *разг.* сызып кую, ясап кую; *начертить чертежей* — чертёжлар сызып кую; 3. язып кую; *начертить слово на камень* — таш өстенә сүз язып кую.

**НАЧЕ'РЧИВАТЬ** *несов. разг.*— к. начертить 2.

**НАЧЕ'РЧИВАТЬСЯ** *несов. страд. разг.*— сызылу, төшерелү.

**НАЧЁС** *м.*— 1. *только ед. спец. (действие)* к. начесать; 2. *(волосы в причёске)* бер тотам чәч (маңгай чәче, чигә чәче); 3. *простореч. (повреждённое чесанием место)* кашып суйдырылган урын; 4. *только ед. (на ткани и трикотаже)* төк, йон; 5. *только ед. спец. (то, что заготовлено чесанием)* тарап хәзерләнгән сүс, тәрәш, тәрәшле.

**НАЧЕСА'ТЬ** *сов.*— 1. *спец.* тарап кую, тарап хәзерләп кую; *начесать льну* — житен тарап хәзерләп кую; 2. *разг.* тарап төшерү; *начесать волос* — чәч тарап төшерү; 3. *разг.* кашып суйдыру; *начесал руку до крови* — кулымны канатканчы кашып суйдырдым.

**НАЧЕСА'ТЬСЯ** *сов. разг.*— туйганчы кашыну.

**НАЧЕ'СТЬ** *сов. редко* — 1. *канц. бухг.* начёт ясау, дөрес тотылмаган расходны расламау, расход тотучының исәбенә язу; 2. *простореч.* к. насчитать 2.

**НАЧЁСЫВАТЬ** *несов.*— к. начесать.

**НАЧЁСЫВАТЬСЯ** *несов. страд.*— тарап куелу, тарап хәзерләп куелу.

**НАЧЁТ** *м. канц. бухг.*— өскә чыгару, начёт (дөрес тотылмаган, шуңа күрә кайтарып бирелергә тиеш булган акча, расланмаган расход).

**НАЧЁТИСТЫЙ** *простореч.*— расходлы, кесәгә зыянлы, өскә чыга торган; *пойдём пешком, а то в оба конца ехать будет начётисто* — әйдә җәяү киттек, юкса утырып баруы да, кайтуы да расходлы булачак.

**НАЧЁТНИЧЕСТВО** *ср.*— хәреф ятлаучылык.

**НАЧЁТЧИК** *м.*— 1. начётчик (староверларда — дини китапларны күп укыган кеше); 2. *перен. ирон.* хәреф ятлаучы, начётчик (күп укыган, ләкин укыганын механик рәвештә генә үзләштергән кеше).

**НАЧИ'Н** *м. обл.*— башлап җибәрү; *сделать что-н. для начину* — башлап җибәрү өчен берәр нәрсә эшләү.

**НАЧИНА'НИЕ** *ср. книж.*— башлап җибәрелгән эш.

**НАЧИНА'ТЕЛЬ** *м.*, **НАЧИНА'ТЕЛЬНИЦА** *ж. устар.*— башлап җибәрүче, нигез салучы, юл салучы.

**НАЧИНА'ТЬ** *несов.*— к. начать.

**НАЧИНА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. башлану; *уличное движение начинается рано* — урамда хәрәкәт иртә башлана; 2. башлану, башланып китү; *река начинается в болотах* — елга сазлыклардан башланып китә.

**НАЧИ'НИВАТЬ** *несов. разг.*— к. начинить II.

**НАЧИНИ'ТЬ** I *сов.*— 1. эченә салу, тутыру; *начинить патрон порохом* — патронга дары тутыру; *начинить пироги мясом* — бәккәннәр эченә ит салу; 2. *перен. разг. ирон.* бирү; *начинить поверхностными знаниями* — өстән-өстән генә белем бирү; 3. *перен. разг. ирон.* бик күп сөйләү; *начинить сплетнями* — бик күп гайбәт сөйләү.

**НАЧИНИ'ТЬ** II *сов. разг.*— 1. (берникадәр) очлау, очлап кую; *начинить карандашей* — карандашлар очлап кую; 2. *(начинить много белья)* ямап чыгу, ямап кую.

**НАЧИНЯ'ТЬ** *несов.*— к. начинить I.

**НАЧИНЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.*— эченә салыну, тутырылу.

**НАЧИ'РКАТЬ** I *сов. разг.*— к. начёркать, начеркать.

**НАЧИ'РКАТЬ** II *сов. разг.*— сызып бетерү (шырпы турында).

**НАЧИ'СЛИТЬ** *сов. бухг.*— арттыру, өстәү; өстәп исәпләү.

**НАЧИСЛЯ'ТЬ** *несов. бухг.* — к. начислить.

**НАЧИСЛЯ'ТЬСЯ** *несов. страд. бухг.*— арттырылу, өстәлү, өстәп исәпләнү.

**НАЧИ'СТИТЬ** *сов.*— 1. (берникадәр) әрчү, әрчеп кую, әрчеп хәзерләп кую; *начистить картошки* — бәрәңге әрчеп кую; 2. *разг.* чистартып кую, тазартып кую; *начистить ботинки* — ботинкаларны тазартып кую.

**НАЧИ'СТИТЬСЯ** *сов. простореч.* — чистарыну.

**НА'ЧИСТО** *нареч.*— 1. акка (язу); *переписать начисто* — акка күчереп язу; 2. *разг.* бөтенләйгә, катгый рәвештә, кискен рәвештә, кырт итеп кисеп; *начисто отказался от платежа* — түләүдән кискен рәвештә баш тартты; 3. *разг. (ничего не скрывая)* бернәрсә дә яшермичә, ачыктан-ачык, турыдан-туры.

**НАЧИСТУ'Ю** *нареч. простореч.*— к. начисто 3.

**НАЧИ'ТАННОСТЬ** *ж. мн.* нет — күп китап укыганлык, күп китап укыган булу.

**НАЧИТА'ТЬ** *сов. разг.* — 1. (берникадәр) уку, укып чыгу; *начитал много книг* — бик күп китап укып чыккан; 2. очрату, (укыганда) табу; *в письме его я начитал две прегрубые ошибки* — аның хатында ике бик тупас хата таптым.

**НАЧИТА'ТЬСЯ** *сов.*— 1. бик күп уку, бик күп укып чыгу; *начитаться романов* — бик күп романнар уку; 2. туйганчы уку, укып тую; *начитаться не могу* — укып туя алмыйм.

**НАЧИ'ТЫВАТЬ** I *несов.*— к. начесть.

**НАЧИ'ТЫВАТЬ** II *несов. разг.*— к. начитать.

**НАЧИ'ТЫВАТЬСЯ** *несов. разг.* — к. начитаться.

**НАЧИХА'ТЬ** *сов. разг.* — 1. *(чихая, забрызгать кого-что-н.)* төчкереп пычрату, төчкереп чәчрәтү; 2. *вульг.* к. начхать.

**НАЧИХА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — туйганчы төчкерү.

**НАЧИЩА'ТЬ** *несов.*— к. начистить.

**НАЧИЩА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. *разг.* к. начиститься; 2. *страд.* әрчеп куелу, әрчеп хәзерләп куелу; чистартып куелу, тазартып хәзерләп куелу.

**НАЧУДЕ'СИТЬ** *сов. фам. ирон.*— к. начудить.

**НАЧУДИ'ТЬ** *сов. разг. фам.*— төрле юләрлекләр эшләп ташлау.

**НАЧХА'ТЬ** *сов. просторeч. вульг.*— төкерү; *начхать мне на его слово* — төкерәм мин аның сүзенә.

**НАШ** *м.* (**наша** *ж.*, **наше** *ср.*, **наши** *мн.*)— 1. *местоим.* безнең; *наша страна* — безнең ил; 2. *разг. в знач. сущ.* үзебезнеке; *нашего не отдадим никому* — үзебезнекен беркемгә дә бирмәбез; 3. *в знач. сущ. и сказ.* безнеке; *наши приехали с дачи* — безнекеләр дачадан кайттылар; *этот дом наш* — бу өй безнеке. ◇ **Поживи с наше**— безнең хәтле яшәп кара әле. **Он стал нашим** — ул безнең (үз) кеше булып китте. **По-нашему** *разг.*— безнеңчә, без уйлаганча. **Наша взяла** — безнеке алдырды, безнекеләр җиңде, без өстен чыктык, без җиңдек, безнең як җиңде. **И нашим и вашим** *разг.* — ике якка да. **Знай наших!** *разг.* — безнекеләр булдыра! безнекеләр иншләтә! **Наше вам (почтение)** *разг. фам.* — сәлам, сәлам бирдек, сәлам бездән.

**НАШАЛИ'ТЬ** *сов. разг.* — шаяру, шуклыклар эшләп ташлау.

**НАШАЛИ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— туйганчы шаяру, шаярып тую.

**НАШАРАМЫ'ЖКУ** — к. нашерамыжку.

**НАША'РКАТЬ** *сов. разг.* — таптап пычратып бетерү; *нашаркать на полу* — идәнне таптап пычратып бетерү.

**НАШАРМАКА'** *нареч. просторeч.*— кеше акчасына, кеше исәбенә.

**НАШАТА'ТЬСЯ** *сов. просторeч.*— туйганчы эшсез йөрү, эшсез йөреп тую.

**НАШАТЫ'РЬ** *м. мн.* нет, *хим.* — нашатырь (техникада һәм медицинада кулланыла торган кристаллы ак матдә).

**НАШВЫРЯ'ТЬ** *сов. разг.* — ыргытып тутыру.

**НАШЕЛУШИ'ТЬ** *сов. разг.* — кабыгын әрчү.

**НА'ШЕНСКИЙ, НА'ШИНСКИЙ** *просторeч.*— безнең; *в знач. сказ.* безнеке.

**НАШЕПТА'ТЬ** *сов.*— 1. (*наговорить шёпотом*) пышылдап сөйләү, пышылдап, колакка әйтү; 2. (*наговорить*) әләкләү, яла ягу; 3. *обл.* өшкерү, әфсенләү; *нашептать на воду* —суга өшкерү.

**НАШЕПТА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — туйганчы пышылдап сөйләшү.

**НАШЁПТЫВАТЬ** *несов.*— к. нашептать.

**НАШЁПТЫВАТЬСЯ** *несов.*— к. нашептаться.

**НАШЕРАМЫ'ЖКУ** *нареч. просторeч.*— алдап, алдаулы юллар белән.

**НАШЕ'СТ** *м. разг.*, **НАШЕ'СТЬ** *ж. обл.*— к. насест.

**НАШЕ'СТВИЕ** *ср.*— 1. басып керү, яу булып килү; һөҗүм, һөҗүм итү; *нашествие Батыя на древнюю Русь в XIII веке* — Батыйның XIII йөздә борынгы Руська басып керүе; 2. *перен. разг. шутл.* ябырылу, ябырылып килү.

**НАШИВА'ТЬ** *несов.*— к. нашить.

**НАШИВА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— өстенә тегеп куелу, тегеп куелу.

**НАШИ'ВКА** *ж.*— 1. *только ед. спец.* (*действие*). к. нашить; 2. *воен.* нашивка (җиңгә яки погонга тегеп куела торган билге).

**НАШИВНО'Й** *порт.*— өстән тегеп куелган, өстән тегеп куела торган; *нашивной карман* — өстән тегеп куелган кесә.

**НАШИ'ЛЬНИК** *м. спец.* — камыт бавы (бер тәртәле арбада).

**НАШИНКОВА'ТЬ** *сов.*— (тар озынча кисәкләргә) турау, турап кую (берникадәр яшелчәне).

**НАШИ'ТЬ** *сов.*— 1. тегеп кую, өстенә тегеп кую; *нашить ленту на шляпу* — эшләпәгә лента тегеп кую; 2. *разг.* (*приготовить шитьём*) тегеп кую, тегеп хәзерләп кую (берникадәр).

**НАШКО'ДИТЬ** *сов. обл.*— 1. (*напачкать*) пычрату, пычратып бетерү; 2. (*устроить беспорядок*) астын-өскә китерү.

**НАШЛЁПАТЬ** *сов.*— 1. *разг. фам.* төшергәләп алу; *нашлёпать ремнём* — каеш белән төшергәләп алу; 2. *просторeч.* таптап эзләр калдыру, таптап пычрату; *нашлёпать на полу* — идәнне таптап пычрату; 3. *просторeч. вульг.* куеп чыгу, басып чыгу; *нашлёпать печатей* — печатьләр басып чыгу.

**НАШЛЯ'ТЬСЯ** *сов. просторeч.* — күп йөрү, эшсез йөрү.

**НАШПА'РИВАТЬ** *несов. просторeч.* — к. нашпарить.

**НАШПА'РИТЬ** *сов. просторeч.*— 1. пешекләп үтерү; *нашпарить клопов* — кандалаларны пешекләп үтерү; 2. (берникадәр) пешекләү; *нашпарить поросят* — дуңгыз балаларын пешекләү.

**НАШПИГОВА'ТЬ** *сов.*— шпиклап хәзерләп кую (куян итен, кош итен һ. б. тишкәләп, дуңгыз мае кисәкләре кыстырып чыгу).

**НАШПИГО'ВЫВАТЬСЯ** *несов. страд.*— шпиклап хәзерләп куелу.

**НАШПИ'ЛИВАТЬ** *несов. разг.*— к. нашпилить.

**НАШПИ'ЛИВАТЬСЯ** *несов. страд. разг.*— (шпилька, булавка белән) кадап куелу.

**НАШПИ'ЛИТЬ** *сов. разг.* — (булавка, шпилька белән) кадау, кадап кую.

**НАШПИО'НИТЬ** *сов. разг. фам.*— әләкләү, серен ачу.

**НАШТО'ПАТЬ** *сов. разг.*— (берникадәр) штопать итү, штопать итеп кую

**НАШУМЕ'ТЬ** *сов.*— 1. (*произвести много шума*) тавыш куптару, тавыш чыгару, тавышлану, кычкырыну, гауга чыгару; 2. *перен.* шаулату; *нашуметь по всему городу* — бөтен шәһәрне шаулату.

**НАШУТИ'ТЬ** *сов. разг.*— шаян сүзләр сөйләп ташлау, мәзәк сүзләр сөйләп ташлау.

**НАШУТИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — туйганчы шаяру.

**НАЩЁЛКАТЬ, НАЩЕЛКА'ТЬ** *сов.* — 1. (*об орехах и т. п.*) яру, ашау (берникадәр); 2. *разг. фам.* (*дать щелчков*) чиртү, чирткәләү; 3. *разг. фам.* (*в драке, сражении*) кирәген бирү.

**НАЩЕПА'ТЬ** *сов. разг.* — (чыра) телгәләп кую, телеп хәзерләп кую (берникадәр).

**НАЩИПА'ТЬ** *сов. разг.* — 1. йолкып җыю; *нащипать травы* — үлән йолкып җыю; 2. *разг.* чеметеп авырттыру; *нащипать щёки* — янакларны чеметеп авырттыру.

**НАЩУ'ПАТЬ** *сов.* — 1. *(ощупывая, найти)* капшап табу, кармалап табу; 2. белеп алу; *нащупать расположение противника* — дошманның урнашкан җирен белеп алу; 3. *перен.* эзләп табу; *нащупать новые источники* — яңа чыганаклар эзләп табу.

**НАЩУ'ПЫВАТЬ** *несов.* — к. нащупать.

**НАЭКОНО'МИТЬ** *сов. разг.* — саклык белән тотып (берникадәр) җыю, саклык белән тотып янга калдыру, экономия ясау.

**НАЭЛЕКТРИЗОВА'ТЬ** *сов.* — 1. *физ.* электрландыру, электрлау; 2. *книж.* тәэсирләндерү, зур тәэсир калдыру, бик нык тәэсир итү, дәрт уяту; *наэлектризовать зрителей* — тамашачыларны бик нык тәэсирләндерү.

**НАЭЛЕКТРИЗОВА'ТЬСЯ** *сов.* — 1. *физ.* электрлану; 2. дәртләнеп китү, тәэсирләнү.

**НАЭЛЕКТРИЗО'ВЫВАТЬ** *несов.* — к. наэлектризовать.

**НАЮРУ' (НА ЮРУ')** *нареч. разг.* — 1. калкулыкта, ачыклыкта; *дом господский стоял одиночкой на юру* — бай йорты калкулыкта бер ялгызы тора иде; 2. уңайсыз җирдә, юл өстендә, һәркем узып йөри торган җирдә; *спать наюру* — юл өстендә ятып йоклау, уңайсыз җирдә ятып йоклау.

**НАЯ'БЕДНИЧАТЬ** *сов. разг.* — әләкләү.

**НАЯВУ'** *нареч.* — өндә (төштә түгел).

**НАЯ'ДА** *ж.* — наяда (1. *миф.* кечкенә елгалардагы һәм инешләрдәге нимфа; 2. *зоол.* Европаның төче суларында яши торган моллюск).

**НАЯ'КОРНИК** *м. спец.* — якорь күчәре (якорьның өске өлешендә була торган агач яки металл күчәр).

**НАЯ'Н** *м. обл.* — бәйләнчек, оятсыз.

**НАЯ'РИВАТЬ** *несов. простореч. шутл.* — әйттерү, теттерү; *парень наяривает на гармонике* — егет гармоньда әйттерә.

**НЕ I** *(без удар). отрицат. частица* — 1. *(при глаголах)* ...-ма; *не ходи* — барма, йөрмә; *не надевай этой шубы* — бу туныны кимә; 2. *(при именах и отрицат. глаголах)* түгел; *он ехал не с сыном, а с дочерью* — ул улы белән түгел, бәлки кызы белән бара иде. ◇ **Мне больше его уже не увидеть** — мин аны артык күрә алмам инде. **Воз не воз, дерево не дерево, а кажется, что шевелится** — йөк дисәң, йөк түгел, агач дисәң, агач түгел, ә үзе селкенгән кебек күренә. **Не худо бы приняться за это дело** — бу эшкә тотынсаң начар булмас иде. **Он человек не без таланта** — ул шактый гына талантлы кеше, ул талантсыз кеше түгел. **Я не мог не засмеяться** — мин көлмичә түзә алмадым, мин көлми кала алмадым. **Нельзя не согласиться** — риза булмаска мөмкин түгел. **Уходи, не то прогонят** — кит, югыйсә куып җибәрерләр. **Не то ехать, не то нет** — әллә барырга, әллә юк; барыргамы, бармаскамы.

**НЕ II** *(всегда с удар.)* — юк; *не о чем говорить* — сөйләр сүз юк; *не от кого узнать* — сорар кеше юк.

**НЕАВАНТА'ЖНЫЙ** *разг. фам.* — 1. начар; 2. *в знач. сказ.* яхшыдан түгел, шәптән түгел; *дела мои неавантажные* — минем эшләр шәптән түгел.

**НЕАККУРА'ТНОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. игътибарсызлык; 2. җыйнаксызлык, шапшаклык.

**НЕАККУРА'ТНЫЙ** — 1. *(неисполнительный, неисправный)* игътибарсыз; тыңлаусыз; вакытында ...-маучан; 2. *(неисправно, неточно, несвоевременно сделанный)* вакытында эшләнмәгән, вакытында үтәлмәгән; төгәл эшләнмәгән; 3. *(небрежный, неопрятный)* шапшак, җыйнаксыз, йобалгы, үзен пычрак тотучан.

**НЕАППЕТИ'ТНЫЙ** — 1. *(не возбуждающий аппетита)* тәмсез; 2. *разг.* кызыксыз; *неаппетитное зрелище* — кызыксыз күренеш.

**НЕАХТИ'** — к. ахти.

**НЕАХТИ'ТЕЛЬНЫЙ** *простореч.* — әллә ни түгел, шәптән түгел; *вид у него неахтительный* — аның кыяфәте шәптән түгел.

**НЕБЕ'ДНЫЙ** *разг.* — шактый бай, хәлле, маллы; *небедный человек* — шактый бай (хәлле) кеше.

**НЕБЕЗВЫ'ГОДНЫЙ** — 1. шактый файдалы; 2. *в знач. сказ.* файдасыз түгел, файдасы юк түгел.

**НЕБЕЗГРЕ'ШНЫЙ** *разг. фам.* — 1. *(неневинный)* берникадәр гөнаһлы, шактый гөнаһлы; *в знач. сказ.* гөнаһсыз түгел, гөнаһы юк түгел; 2. законсыз, законсыз юл белән килгән, законсыз юл белән табылган; *небезгрешные доходы* — законсыз юл белән килгән доходлар.

**НЕБЕЗДА'РНЫЙ** *разг.* — 1. шактый талантлы; *небездарный поэт* — шактый талантлы шагыйрь; 2. *в знач. сказ.* бөтенләй үк сәләтсез түгел.

**НЕБЕЗНАДЁЖНЫЙ, НЕБЕЗНАДЕ'ЖНЫЙ** — 1. шактый гына ышанычлы, өметле; *небезнадёжное дело* — шактый гына ышанычлы эш; 2. *в знач. сказ.* ышанычны югалтырлык түгел, ышанычсыз түгел, өметсез түгел.

**НЕБЕЗОБИ'ДНЫЙ** *разг.* — 1. *(достаточно обидный)* шактый гына хәтер калдырырлык, үпкәләтерлек, рәнҗетерлек; 2. хәтер сакламаучан, хәтер саклаучы торган, хәтер калдыручан, рәнҗетүчән, каты сүзле; *он человек небезобидный* — ул хәтер калдыручан кеше.

**НЕБЕЗОПА'СНЫЙ** — 1. шактый куркынычлы, хәвеф-хәтәрле; 2. *в знач. сказ.* куркынычсыз түгел.

**НЕБЕЗОСНОВА'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.* — 1. нигезле; 2. *в знач. сказ.* нигезсез түгел.

**НЕБЕЗРАЗЛИ'ЧНЫЙ** — 1. кызыксынып..., игътибар белән...; *небезразличное отношение к делу* — эшкә кызыксынып карау;

2. *в знач. сказ.* барыбер түгел; *её судьба мне небезразлична* — аның язмышы минем өчен барыбер түгел.

**НЕБЕЗРАССУ'ДНЫЙ** — шактый гына акыллы, төпле, уйлап әйтелгән (бирелгән), шактый гына уйланган; *небезрассудный совет* — уйлап бирелгән киңәш.

**НЕБЕЗРЕЗУЛЬТА'ТНЫЙ** — 1. нәтиҗәле, шактый гына нәтиҗәле; 2. *в знач. сказ.* нәтиҗәсез түгел.

**НЕБЕЗУКОРИ'ЗНЕННЫЙ** *книж.*— 1. житешсез яклары булган, мактамаслык, шелтәләрлек, шелтә тидерерлек; 2. *в знач. сказ.* мактарлык түгел, шелтәләмәслек түгел, тел тидермәслек түгел.

**НЕБЕЗУПРЕ'ЧНЫЙ** *книж.* — 1. шелтәләрлек, житешсез яклары булган; 2. *в знач. сказ.* сүз әйтмәслек түгел, тел тидермәслек түгел, һәр яктан да килеп житкән диярлек түгел.

**НЕБЕЗУСПЕ'ШНЫЙ** *книж.* — 1. шактый гына уңышлы; 2. *в знач. сказ.* уңышсыз түгел.

**НЕБЕЗЫЗВЕ'СТНЫЙ** *чаще ирон.*— билгеле булган, атаклы, шактый гына танылган; *небезызвестный писатель* — шактый гына танылган язучы.

**НЕБЕЗИНТЕРЕ'СНЫЙ** — шактый гына кызыклы; *небезинтересный случай* — шактый гына кызыклы вакыйга.

**НЕБЕРУ'ЩИЙ** *разг. шутл. устар.* — взятка (ришвәт) алмаучы, взятка (ришвәт) алмый торган.

**НЕБЕСА'** *мн.* (*ед. небо*) — күкләр; *превозносить до небес* — күкләргә күтәрү (чиктән тыш олылау, мактау).

**НЕБЕСКОРЫ'СТНЫЙ** — хирыслы уйлар белән...; *небескорыстное участие* — хирыслы уйлар белән катнашу.

**НЕБЕ'СНЫЙ** — 1. күк...-ы, күктәге; *небесный свод* — күк гөмбәзе; *небесные тела* — күк жисемнәре; 2. *разг.* аксыл күк, аксыл зәңгәр; *в одежде небесного цвета* — аксыл күк төстәге киемнән; 3. *перен. поэт. устар.* гүзәл, матур, искиткеч матур, сокланырлык; *небесная улыбка* — гүзәл елмаю.◇ **Как птица небесная** *разг. шутл.*— һавадагы кош кебек (кайгысыз тору). **Царь небесный** *религ.*— тәңре. **Царство небесное** *религ.*— җәннәт.

**НЕБЕСПОЛЕ'ЗНЫЙ** — 1. шактый гына файдалы; 2. *в знач. сказ.* файдасыз түгел.

**НЕБЕССПО'РНЫЙ** *книж.* — 1. шактый бәхәсле, ачыкланып җитмәгән; 2. *в знач. сказ.* бәхәссез түгел.

**НЕБЕСТАЛА'ННЫЙ** *разг.*— шактый гына талантлы.

**НЕБЛАГОВИ'ДНЫЙ** — 1. *устар.* ямьсез, шыксыз; *вошёл неблаговидный лакей* — шыксыз бер лакей килеп керде; 2. ямьсез, ярамаган, гаеп итәрлек, начар; *неблаговидный поступок* — ямьсез кыланыш.

**НЕБЛАГОВОСПИ'ТАННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *устар.* — әдәпсезлек, тәртипсезлек, үзен-үзе тота белмәү(чәнлек).

**НЕБЛАГОВОСПИ'ТАННЫЙ** *устар.* — әдәпсез, тәртипсез, үзен-үзе тота белмәүчән.

**НЕБЛАГОДА'РНОСТЬ** *ж. мн.* нет — яхшылыкның кадерен белмәү. ◇ **Отплатить** *кому-н.* **чёрной неблагодарностью** — яхшылыкка яманлык белән кайтару.

**НЕБЛАГОДА'РНЫЙ** — 1. яхшылыкны белмәгән, яхшылыкның кадерен белмәүче, яхшылыкның кадерен белмәүчән; *неблагодарный человек* — яхшылыкның кадерен белмәүче кеше; 2. нәтиҗәсез, уңышсыз, файдасыз, әрәм; *неблагодарный труд* — нәтиҗәсез хезмәт; 3. *разг. (не соответствующий каким-н. требованиям)* яраксыз, туры килми торган; *неблагодарная для сцены внешность* — сәхнә өчен туры килми торган кыяфәт (тышкы күренеш).

**НЕБЛАГОЖЕЛА'ТЕЛЬНЫЙ** *книж. устар.*— к. недоброжелательный.

**НЕБЛАГОЖЕЛА'ТЕЛЬСТВО** *книж. устар.*— к. недоброжелательство.

**НЕБЛАГОЗВУ'ЧИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.*— аһәңсезлек.

**НЕБЛАГОЗВУ'ЧНЫЙ** *книж.* — аһәңсез.

**НЕБЛАГОНАДЁЖНОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. *разг.* ышанычсызлык, ышанычсыз булу; 2. *офиц. дореvол.* шикле булу, шик астына алынганлык (патша Россиясендә самодержавиегә каршы революцион эшчәнлектә, революцион хәрәкәткә теләктәшлек күрсәтүдә гаепләнеп полиция тарафыннан шик астына алынганлык).

**НЕБЛАГОНАДЁЖНЫЙ** — 1. ышанычсыз; *неблагонадёжная постройка* — ышанычсыз бина (корылма); 2. *офиц. дореvол.* шикле, шик астына алынган (кеше).

**НЕБЛАГОПОЛУ'ЧИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.*— тынычсызлык, уңышсызлык.

**НЕБЛАГОПОЛУ'ЧНО** *нареч.*— 1. уңышсыз, начар; 2. *безл. в знач. сказ.* имин түгел, тыныч түгел, шәптән түгел; *у них в семье неблагополучно* — аларның семьясында эшләр шәптән түгел.

**НЕБЛАГОПОЛУ'ЧНЫЙ** — 1. уңышсыз, начар; *неблагополучный исход дела* — эшнең уңышсыз нәтиҗәсе; 2. *офиц.* имин булмаган, хәвеф-хәтәрле, куркынычлы; *неблагополучная по малярии местность* — малериядән имин булмаган урын; 3. *(об учреждении, предприятии)* эшләре начар бара торган; артка калган.

**НЕБЛАГОПРИСТО'ЙНОСТЬ** *ж. устар.*— 1. *только ед.* әдәпсезлек, килешсезлек, сансызлык, оятсызлык, начарлык; 2. килешсез сүз (кыланыш, эш), кабахәт сүз (кыланыш, эш), начар сүз (кыланыш, эш).

**НЕБЛАГОПРИСТО'ЙНЫЙ** *устар.*— әдәпсез, килешсез, сансыз, оятсыз, начар.

**НЕБЛАГОПРИЯ'ТНЫЙ** — уңайсыз, җайсыз, начар, күңелсез; тискәре; бозык.

**НЕБЛАГОРАЗУ'МИЕ** *ср. мн.* нет — акылсызлык, аңсызлык, дуамаллык.

**НЕБЛАГОРАЗУ'МНЫЙ** *книж.*—акылсыз, аңсыз, дуамал, акылга сыймаслык, уйламыйча эшләнгән.

**НЕБЛАГОРО'ДНЫЙ** — 1. затсыз, түбән; намуссыз, ямьсез; *неблагородный поступок* — ямьсез кыланыш, намуссыз кыланыш; *неблагородный человек* — түбән кеше; 2. *устар.* тупас, дорфа; *телодвижения неприятны, неблагородны* — аның тән хәрәкәтләре ямьсез, дорфа; 3. затсыз; *неблагородные металлы* — затсыз металлар (мәсәлән, тимер, бакыр). ◇ **Человек неблагородного звания** *дорев. вол.* — дворяннар нәселеннән булмаган кеше.

**НЕБЛАГОРО'ДСТВО** *ср. мн.* нет, *книж.* — затсызлык, намуссызлык, түбәнлек.

**НЕБЛАГОСКЛО'ННОСТЬ** *ж. мн.* нет — ягымсызлык, салкынлык.

**НЕБЛАГОСКЛО'ННЫЙ** *книж.* — ягымсыз, салкын; *неблагосклонный взгляд* — салкын караш. ◇ **Неблагосклонный ответ** — тискәре җавап, салкын җавап (ягъни сораучының үтенечен канәгатьләндермичә бирелгән җавап).

**НЕБЛАГОТВО'РНЫЙ** *книж.* — зарарлы, начар.

**НЕБЛАГОУСТРО'ЕННЫЙ** *книж.* — тәртипкә салынмаган, төзек булмаган.

**НЕБЛЕСТЯ'ЩИЙ** *разг.* — 1. начар; 2. *в знач. сказ.* яхшыдан түгел, шәптән түгел, яхшы бармый; *дела мои неблестящи* — минем эшләр шәптән түгел.

**НЁБНЫЙ** — аңкау...-ы; *нёбная полость* — аңкау куышлыгы; *нёбные звуки* — аңкау авазлары. ◇ **Нёбная занавеска** — кече тел.

**НЕ'БО** *ср.* — 1. күк, күк йөзе; *тучи обложили небо* — болытлар күкне каплап алган; 2. *книж. устар.* (*божественная сила*) тәңре; 3. *обл. спец.* түшәм, түбә; *небо шахты* — шахта түбәсе. ◇ **Под открытым небом** — ачык һавада, яланда, далада. **На седьмом небе** *разг.* — түбәсе күккә тигән. **Попасть пальцем в небо** *разг. ирон.* — дуга белән печән чабу (бик нык ялгышу). **Небо с овчинку (показалось)** *разг.* — котым очты (бик нык курыктым). **Небу жарко (станет)** *разг.* — кая барырга белмәссең, кая керергә тишек таба алмассың. **Небо коптить** *разг. пренебр.* — күкне киптерү (вакытны файдасызга үткәрү, тик йөрү). **Между небом и землей (жить, быть, находиться)** *разг.* — җир белән күк арасында (яшәү, булу).

**НЁБО** *ср.* — 1. *анат.* аңкау; 2. *обл.* мич көймәсе.

**НЕБОГА'ТЫЙ** — 1. *устар.* урта хәлле; *сын небогатых родителей* — урта хәлле кешеләрнең улы; 2. *устар.* уртача гына ...-ган, гади генә ...-ган; *небогатый кабинет* — уртача гына җиһазландырылган кабинет; 3. *в знач. сказ. перен.* ярлы, бай түгел; *небогат словами* — сүзгә ярлы (бай түгел).

**НЕБОКОПТИ'ТЕЛЬ** *м. устар. презрит.* — тик ятучы, эшлексез, ялкау.

**НЕБОЛЬШО'Й** — 1. кечкенә; зур булмаган; *небольшой пароход* — кечкенә пароход; 2. аз гына, аз; *небольшой срок* — аз вакыт; *небольшое размышление* — аз гына уйлап карау; 3. *в знач. сказ.* зур түгел. ◇ **С небольшим** — аз гына артык; *кило с небольшим* — килодан аз гына артык. **За небольшим дело стало или остановилось** *разг.* — эш кечкенәдә калды, эш азда гына калды.

**НЕБОСВО'Д** *м. мн.* нет, *книж. поэт.* — күк гөмбәзе.

**НЕБОСКЛО'Н** *м. мн.* нет, *книж. поэт.* — күк йөзе (күкнең офык өстендәге өлеше).

**НЕБОСКРЁБ** *м. мн.* нет, *книж. поэт.* — бик биек йорт.

**НЕБО'СЬ** *просторен.* — 1. *ввод. сл.* (*вероятно*) булса кирәк; 2. *ввод. сл.* (*в вопросит. предл.*) ...-дыр мөгаен; *испугались, небось?* — курыккансыздыр мөгаен? 3. *ввод. сл.* (*ведь, уж конечно*) ... ләбаса, билгеле инде; 4. *в знач. сказ. устар. обл.* курыкма; *небось, собака моя не кусается!* — курыкма, минем этем тешләми. ◇ **Авось да небось (авось, небось да как-нибудь)** — к. авось.

**НЕБРЕЖЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж. устар.* — 1. (*нерадивое отношение*) саксызлык, игътибарсызлык, салкын караш; 2. (*пренебрежение, невнимание*) игътибарсызлык, санга алмау, санга сукмау; кимсетеп карау, түбәнсетеп карау.

**НЕБРЕ'ЖНИЧАТЬ** *несов. разг.* — салкын карау, игътибарсыз карау, тырышлык күрсәтмәү, саксызлык (игътибарсызлык) күрсәтү.

**НЕБРЕ'ЖНОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. житкереп эшләнмәгән булу, игътибарсыз эшләнү, ничек житте шулай эшләнү; *небрежность работы* — эшнең игътибарсыз башкарылуы; 2. кытыршылык; *небрежность стиля* — стильнең кытыршылыгы; 3. җыйнаксызлык, игътибарсызлык, игътибарсыз караш, салкын караш; *возмутительная небрежность* — ачу китергеч игътибарсызлык. ◇ **По небрежности** — игътибарсызлык аркасында. **Одеться с умышленной небрежностью** — юри җыйнаксыз киенү.

**НЕБРЕ'ЖНЫЙ** — 1. (*о человеке*) (эшенә) игътибарсыз караучан, (эшенә) салкын караучан; 2. начар эшләнгән, ничек житте шулай эшләнгән, игътибарсыз эшләнгән, тырышып эшләнмәгән; *небрежная работа* — игътибарсыз башкарылган эш; 3. кытыршы; *небрежный стиль* — кытыршы стиль; 4. дорфа, тупас; *небрежные манеры* — дорфа кыланышлар. ◇ **Ответить небрежным кивком головы** — эре генә баш иеп җавап бирү.

**НЕБРЕ'ЧЬ** *несов. книж. устар.* — искитмәү, санга алмау, санга сукмау; игътибар итмәү.

**НЕБРИ'ТЫЙ** — 1. кырынмаган; *небритый человек* — кырынмаган кеше; 2. кырылмаган; *небритая борода* — кырылмаган сакал.

**НЕБЫВА'ЛЫЙ** — 1. әлегәчә булмаган, гадәттән тыш, искиткеч, күрелмәгән, гомердә булмаган, һич булмаган, охшашытиндәше булмаган; *небывалое происшествие* — әлегәчә булмаган (искиткеч) вакыйга;

2. *(вымышленный)* һич булмаган, уйлап чыгарылган, уйдырма...; 3. *разг.* *(не имеющий житейского опыта)* дөнья күрмәгән, тәҗрибәсез.

**НЕБЫВА'ЛЬЩИНА** — 1. *разг. устар.* к. небылица; 2. *разг. (то, чего не было, не бывает)* булмаган нәрсә (эш), уйдырма; 3. *лит. (сказка, выдумка)* әкият.

**НЕБЫЛИ'ЦА** *ж.*— ялган, уйдырма, кеше ышанмаслык нәрсә, тузга язмаган сүз (хәбәр).

**НЕ'БЫЛЬ** *ж. обл.*— к. небывальщина 2.

**НЕБЫТИЕ'** *ср. мн.* нет, *книж. устар.*— юклык (яшәешнең юклыгы).

**НЕВА'ЖНЫЙ** *разг.* — 1. *(мало значительный, мелкий)* әһәмиятсез, кечкенә, вак; 2. *(посредственный, плоховатый)* бертөрле, уртача; 3. *в знач. сказ.* шәптән түгел, начар, хөрти.

**НЕВДАЛЕКЕ'** *нареч.*— шунда гына, якында гына, ерак түгел.

**НЕВДОГА'Д** *нареч. в знач. сказ. разг.*— к. невдомёк.

**НЕВДОМЁК** *нареч. в знач. сказ. разг.*— сизмәү, сизми калу, белми калу, башка килмәү; төшенә алмау, аңлый алмау; *ему и невдомёк* — аның башына да килми; *мне невдомёк, чего он хочет* — аның нәрсә теләгәнен мин аңлый алмыйм.

**НЕВЕГЛА'С** *м. старин.*— к. невежда.

**НЕВЕ'ДАННЫЙ** *книж.*— серле, билгеле булмаган.

**НЕВЕ'ДЕНИЕ** *ср. мн.* нет — белмәү, хәбәрдар булмау, хәбәрсезлек, мәгълүматсызлык. ◇ **В блаженном неведении** — рәхәт, кайгы-хәсрәтсез.

**НЕВЕ'ДОМО** *нареч. разг. пренебр.*: **неведомо что** — белмим нәрсә, әллә нәрсә; **неведомо кто** — белмим кем, әллә кем; **неведомо когда** — белмим кайчан.

**НЕВЕ'ДОМЫЙ** — 1. *(неизвестный)* танылмаган, билгесез, билгеле булмаган; 2. *(таинственный, чудесный)* гаҗәп, серле, яшерен, билгесез.

**НЕВЕ'ЖА** *м.* и *ж.*— 1. тупас, дорфа (кеше); 2 *разг. устар.* к. невежда.

**НЕВЕ'ЖДА** *м. неодобр.*— надан, белемсез, томана. ◇ **Круглый невежда** — чеп-чи надан, әлифне таяк дип белми.

**НЕВЕ'ЖЕСТВЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *неодобр.*— наданлык.

**НЕВЕ'ЖЕСТВЕННЫЙ** *неодобр.*— надан, белемсез.

**НЕВЕ'ЖЕСТВО** *ср. неодобр.*— 1. *(отсутствие познаний, отсталость)* наданлык, белемсезлек, мәгълүматсызлык, караңгылык; 2. *разг. (невоспитанность)* культурасызлык, әдәпсезлек, тәрбиясезлек.

**НЕВЕ'ЖЛИВОСТЬ** *ж. мн.* нет — әдәпсезлек, тәрбиясезлек, нәзакәтсезлек, тупаслык, дорфалык.

**НЕВЕ'ЖЛИВЫЙ** — әдәпсез, тәрбиясез, нәзакәтсез, тупас, дорфа.

**НЕВЕ'ЖНИЧАТЬ** *несов. разг.* — тупас кылану, дорфа кылану, әдәпсезләнү, тәрбиясезләнү.

**НЕВЕЗЕ'НИЕ** *ср. разг.* — уңышсызлык, эшләрнең гел кирегә китеп торуы.

**НЕВЕЛИ'ЧКА** *м.* и *ж. обл.*: **ростом невеличка** — кечкенә буйлы; **птичка-невеличка** — кошчык, кечкенә кош.

**НЕВЕ'РИЕ** *ср. мн.* нет — 1. *(отсутствие веры)* ышанмау; 2. *(атеизм)* аллага ышанмау, динсезлек.

**НЕВЕ'РНОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. хаталык, ялгышлык, дөрес булмау, дөрес түгеллек; *неверность вычислений* — исәпләүнең хаталыгы; 2. *(измена дружбе и т. п.)* хыянәт, хыянәт итү.

**НЕВЕ'РНЫЙ** — 1. хата..., ялгыш; *неверное вычисление* — хата исәпләү; 2. ялган, ышанычсыз; дөрес булмаган; *неверное сообщение* — ялган (ышанычсыз) хәбәр; 3. ышанычсыз, мөнафыйк, хыянәт итүче; *неверный муж* — хыянәт итүче ир; *неверный человек* — мөнафыйк кеше; 4. *в знач. сущ. устар. (исповедующий чужую веру)* башка дин тотучы; 5. *обл. (недоверчивый)* ышанмаучан; 6. *в знач. сказ.* дөрес түгел, хата, ялгыш. ◇ **Фома неверный** *разг.*— ышанмаучан, бернәрсәгә дә ышанмый торган кеше. **Неверная походка** — кыюсыз йөрү, кыюсыз атлап йөрү.

**НЕВЕРОЯ'ТИЕ** *ср. устар.*— к. невероятность.

**НЕВЕРОЯ'ТНОСТЬ** *ж.*— 1. акылга сыймаслык булу; кеше ышанмаслык булу; 2. акылга сыймаслык хәбәр (вакыйга), кеше ышанмаслык хәбәр (вакыйга). ◇ **До невероятности** — чиктән тыш.

**НЕВЕРОЯ'ТНЫЙ** — 1. *(неправдоподобный)* ышанмаслык, кеше ышанмаслык, акылга сыймаслык; *в знач. сказ.* ышанырлык түгел; 2. гадәттән тыш (көчле, зур), бик зур; *невероятный успех* — гадәттән тыш зур уңыш.

**НЕВЕ'РУЮЩИЙ** — динсез, аллага ышанмаучы, дингә ышанмаучы.

**НЕВЕСЁЛЫЙ** — 1. күңелсез, ямансу, төмсә, кайгылы; *невесёлое настроение* — күңелсез настроение; 2. күңелсез, кызыксыз; ямьсез; *невесёлое положение* — кызыксыз хәл.

**НЕВЕСО'МЫЙ** *книж.*— 1. авырлыксыз, авырлыгы булмаган; *в начале XIX века теплота и электричество считались невесомыми жидкостями* — XIX йөз башында җылылык һәм электр авырлыксыз сыекчалар дип исәпләнәләр иде; 2. *перен. редко* сизелмәслек, беленмәслек, әһәмиятсез, игътибар итмәслек; *невесомые аргументы* — әһәмиятсез (игътибар итмәслек) аргументлар.

**НЕВЕ'СТА** *ж.*— 1. ярәшкән кыз, кәләш; 2. *разг.* буйга җиткән кыз. ◇ **Христова невеста** — 1. монашка; 2. *шутл. ирон.* карт кыз, утырып калган кыз, сазаган кыз.

**НЕВЕ'СТИТЬСЯ** *несов. обл.* — буйга җитү (кызлар турында).

**НЕВЕ'СТКА** *ж.* — 1. *(жена сына, младшего брата)* килен; 2. *(жена старшего брата)* җиңгә; 3. *(жёны двух братьев)* килендәш.

**НЕВЕ'СТЬ, НИВЕ'СТЬ** *нареч. простореч. (употребл. с относит. местоим. и наречиями)*— әллә, белмим; *невесть что*

(*чего*) — әлләниләр; *невесть когда* — белмим кайчан; *невесть чем* — белмим нәрсә(се) белән.

**НЕВЕЩЕ'СТВЕННЫЙ** — рухи, материаль булмаган, абстракт.

**НЕВЗАЧЁТ** *нареч. разг.* — саналмас, саналмый, исәпкә алынмас, исәпкә алынмый; *первое опоздание вам будет невзачёт* — сезнең беренче тапкыр соңга калуыгыз исәпкә алынмас.

**НЕВЗВИ'ДЕТЬ** или **НЕ ВЗВИ'ДЕТЬ** — к. взвидеть.

**НЕВЗГО'ДА** *ж.* — авырлык, кыенлык; авыр кичерешләр, уңышсызлык; кайгы-хәсрәт; бәла.

**НЕВЗГО'ДЬЕ** *ср. устар.* — к. невзгода.

**НЕВЗИРА'Я** или **НЕ ВЗИРА'Я** — к. взирать.

**НЕВЗЛЮБИ'ТЬ** или **НЕ ВЗЛЮБИ'ТЬ** — к. взлюбить.

**НЕВЗНАЧА'Й** *нареч. разг.* — көтмәгәндә, абайламастан, абайламыйча; ялгышлык белән, искәрмәстән.

**НЕВЗРА'ЧНЫЙ** — шыксыз, ямьсез, килбәтсез, күрексез, күренексез.

**НЕВЗЫСКА'ТЕЛЬНЫЙ** — 1. (*нетребовательный*) талымсыз, әрсез; *в знач. сказ.* таләпчән түгел, талымсыз; 2. *редко* (*простой, самый обыкновенный*) гади, гадәти.

**НЕ'ВИДАЛЬ** *ж. мн.* нет, *разг. ирон.*: экая (или эка) невидаль! вот невидаль!— искиткеч әйбер икән! искиткеч хәл икән! исең киткән икән! что за невидаль!— бу нинди гаҗәп әйбер! бу нинди искиткеч нәрсә!

**НЕВИДА'ЛЬЩИНА** *ж. разг. устар.* — к. невидаль.

**НЕВИ'ДАННЫЙ** — 1. (*небывалый*) искиткеч, гомердә булмаган, әлегәчә булмаган, әлегәчә күрелмәгән, моңарчы күрелмәгән; 2. (*странный, таинственный*) гаҗәп; серле.

**НЕВИДИ'МКА** *м.* и *ж. фольк.*— күзгә күренми торган кеше (гомумән җан иясе). ◇ Невидимкою *нареч.* — күренмичә генә, сиздермичә генә, яшерен генә, астыртын гына. Шапка-невидимка *фольк.* — кешене күренмәс итә торган тылсымлы бүрек. Шпильки-невидимки — нечкә һәм кечкенә шпилькалар.

**НЕВИ'ДИМО** *нареч.* — күренмичә генә, сиздермичә генә.

**НЕВИ'ДИМЫЙ** — күзгә күренми торган, күзгә күренмәгән.

**НЕВИ'ННО** *нареч.*— гаепсезгә, хаксызга, нахакка; *много слёз горьких невинно я лила* (Лермонтов) — хаксызга бик күп ачы күз яшьләре түктем мин.

**НЕВИ'ННОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. сафлык, гаепсезлек, гөнаһсызлык; 2. (*целомудрие*) сафлык, гыйффәтлелек.

**НЕВИ'ННЫЙ** — 1. гаепсез, гаебе булмаган, гөнаһсыз, катнашы булмаган; *невинные люди* — гаепсез кешеләр; 2. (*наивный, чистосердечный*) саф күңелле, эчкерсез, хәйләсез, беркатлы; 3. (*безвредный, непредосудительный*) гаеп итмәслек, гаепкә алмаслык, зарарсыз; 4. (*девственный*) саф, бозылмаган, гыйффәтле.

**НЕВИНО'ВНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — гаепсезлек.

**НЕВИНО'ВНЫЙ** — гаепсез.

**НЕВКУ'СНЫЙ** — тәмсез.

**НЕВЛА'СТНЫЙ** — властьсыз, көчсез.

**НЕВМЕНЯ'ЕМОСТЬ** *ж. мн.* нет, *право* — үзен-үзе белмәү, ни эшләгәнен белмәү (психик хәл; мондый психик хәлдә булган кеше җинаяте өчен җавапка тартылмый).

**НЕВМЕНЯ'ЕМЫЙ** — 1. *право* үзен-үзе белмәгән кеше (үзенең психик хәле буенча, җинаяте өчен җавапка тартыла алмый торган кеше); 2. *разг.* ни эшләгәнен белми торган; *он был невменяем от гнева* — ул ачуыннан ни эшләгәнен белми иде.

**НЕВМЕ'СТНЫЙ** *устар.* — килешмәгән, тиеш булмаган, килешми торган; 2. *в знач. сказ.* килешми, тиеш түгел.

**НЕВМЕША'ТЕЛЬСТВО** *ср. мн.* нет, *право, полит.* — катнашмау, катнашмаучылык; *политика невмешательства* — катнашмау(чылык) политикасы (икенче бер дәүләтнең эчке эшләренә катнашмау).

**НЕВМОГОТУ'** *нареч. в знач. сказ. разг.*— чыдар хәл калмады, чыдар хәл юк; *мне уже невмоготу* — минем чыдар хәлем юк инде, минем чыдар хәлем калмады инде.

**НЕВМО'ЧЬ** *нареч. в знач. сказ. разг.* — к. невмоготу.

**НЕВНИМА'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — 1. (*рассеянность*) игътибарсызлык, таркаулык, саксызлык, онытучанлык, хәтер чуалчыклыгы; 2. (*отсутствие уважения, учтивости*) игътибарсызлык, ихтирамсызлык.

**НЕВНИМА'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж.* — игътибарсызлык.

**НЕВНИМА'ТЕЛЬНЫЙ** — 1. (*рассеянный*) игътибарсыз, гамьсез, саксыз, таркау; онытучан; 2. (*неучтивый, невежливый*) игътибарсыз; ихтирамсыз, дорфа, тупас.

**НЕВНЯ'ТИЦА** *ж. разг.* — аңлаешсыз сүзләр.

**НЕВНЯ'ТНЫЙ** — 1. (*плохо слышный*) ишетелер-ишетелмәс; аңлашылыр-аңлашылмас; 2. (*невразумительный*) аңлаешсыз.

**НЕ'ВОД** *м.* — җылым, шәпкә (балык тотуда кулланыла торган иң зур җәтмә).

**НЕ'ВОДИТЬ** *несов. спец.* — җылым (шәпкә) белән балык тоту.

**НЕ'ВОДЧИК** *м. спец.* — җылым (шәпкә) белән балык тотучы.

**НЕВОЗБРА'ННЫЙ** *книж. устар.*—1. (*незапрещённый*) тыелмаган, тыюсыз; 2. (*беспрепятственный*) тоткарсыз, комачаусыз.

**НЕВОЗВРАТИ'МЫЙ** *книж.* — к. невозвратный.

**НЕВОЗВРА'ТНО** *нареч.*— кайтмаска, мәңгегә, гомергә.

**НЕВОЗВРА'ТНЫЙ** *книж.* — кайтмас, кайтарылмаслык, кайтаруы мөмкин булмаган, кире кайтмый торган, кабатланмый торган.

**НЕВОЗГОРА'ЕМОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — к. невоспламеняемость.

**НЕВОЗДЕРЖА'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.*— тотнаксызлык, тыйнаксызлык.

**НЕВОЗДЕ'РЖАННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — тотнаксызлык, тыйнаксызлык.

**НЕВОЗДЕ'РЖАННЫЙ** *разг.* — к. невоздержный.

**НЕВОЗДЕ'РЖНОСТЬ** *ж. мн.* нет — к. невоздержанность.

**НЕВОЗДЕ'РЖНЫЙ** — 1. *(предающийся излишествам)* тотнаксыз, тыйнаксыз; үзен-үзе тыя белмәүчән, үзен-үзе тыя алмаучан; 2. *(неосторожный)* саксыз; сабырсыз.

**НЕВОЗМО'ЖНО** *нареч.* — 1. бик начар; *вести себя невозможно* — үзенне бик начар тоту; 2. *разг.* бик, искиткеч; *у вас невозможно узкая грудь* — сезнең күкрәгегез бик тар; 3. *в знач. сказ.* мөмкин түгел.

**НЕВОЗМО'ЖНОСТЬ** *ж. мн.* нет — мөмкин булмау, мөмкин түгеллек. ◇ **До невозможности** *разг. фам.* — бик, чиктән тыш.

**НЕВОЗМО'ЖНЫЙ** — 1. *(неосуществимый, невыполнимый)* тормышка ашыруы мөмкин булмаган, тормышка ашырыла алмаслык, мөмкин булмаган; 2. *разг.* *(невыносимый, очень сильный)* чыдамаслык, чиктән тыш авыр (каты), түзә алмаслык, бик каты; 3. *разг.* *(недопустимый, возмутительный)* һич тә ярамый торган, яраксыз, начар, ачу китергеч.

**НЕВОЗМУТИ'МОСТЬ** *ж. мн.* нет — тынычлык, каушап калмаучанлык, борчылмаучанлык.

**НЕВОЗМУТИ'МЫЙ** — 1. *(спокойный)* тыныч, борчылмый торган, каушап калмый торган, пошынмый торган, бернәрсәгә дә исе китми торган; 2. тулы; *невозмутимая тишина* — тулы тынлык.

**НЕВОЗНАГРАДИ'МЫЙ** *книж.* — 1. кайтара алмаслык, кайтмас, кайтаруы мөмкин булмаган; *невознаградимая утрата* — кәйтара алмаслык югалту; 2. *редко* бик зур, һәртөрле бүләкләрдән өстен.

**НЕВО'ЛЕЙ** *нареч. устар.* — ирексез, ирексездән, көчләп, теләккә каршы. ◇ **Волей-неволей** — ирекле-ирексез, теләсә-теләмәсә дә, ихтыярлы-ихтыярсыз.

**НЕВО'ЛИТЬ** *несов.* — 1. *(принуждать)* ирексезләү, көчләү, мәҗбүр итү; 2. *устар.* *(притеснять, порабощать)* кол итү, коллыкка төшерү.

**НЕВО'ЛЬНИК** *м.*, **НЕВО'ЛЬНИЦА** *ж.* *книж. устар.* — 1. *(раб)* кол; 2. *(пленник, заключённый)* тоткын, әсир.

**НЕВО'ЛЬНИЧЕСТВО** *ср. мн.* нет, *книж. устар.* — коллык, әсирлек.

**НЕВО'ЛЬНИЧИЙ**: невольничий труд — коллар хезмәте, тоткыннар хезмәте.

**НЕВО'ЛЬНО** *нареч.* — ихтыярсыз, ирексездән, абайламыйча, теләмәстән.

**НЕВО'ЛЬНЫЙ** — 1. *(неумышленный, случайный)* очраклы, ялгыш әйтелгән (эшләнгән), уйланмый әйтелгән; ансыздан..., абайламыйча...; 2. ихтыярсыз эшләнгән; ирексездән эшләнгән; 3. *устар.* *(лишённый свободы)* иректән мәхрүм ителгән.

**НЕВО'ЛЮШКА** *ж. мн.* нет, *нар.-поэт.*— к. неволя.

**НЕВО'ЛЯ** *ж. мн.* нет — 1. *(рабство)* коллык; 2. *(плен)* әсирлек, тоткынлык; 3. *(нужда)* ихтыяҗ, мохтаҗлык.

**НЕВООБРАЗИ'МЫЙ** — күз алдына китерә алмаслык, күз алдына да китергесез, уйларга да мөмкин булмаган; гадәттән тыш, искиткеч.

**НЕВООРУЖЁННЫЙ** — коралсыз, коралланмаган. ◇ **Невооружённый глаз** — гади күз; *бактерии нельзя видеть невооружённым глазом* — бактерияләрне гади күз белән күреп булмый.

**НЕВОСПИ'ТАННОСТЬ** *ж. мн.* нет — әдәпсезлек, тәрбиясезлек, дорфалык, тупаслык.

**НЕВОСПИ'ТАННЫЙ** — әдәпсез, тәрбиясез, дорфа, тупас.

**НЕВОСПЛАМЕНЯ'ЕМОСТЬ** *ж. мн.* нет, *спец.* — үзеннән-үзе кабынмаучанлык, үзеннән-үзе кабынып китмәүчәнлек, үзеннән-үзе кабынмау.

**НЕВОСПЛАМЕНЯ'ЕМЫЙ** *спец.* — үзеннән-үзе кабынмый торган, үзеннән-үзе кабынып китми торган.

**НЕВОСПРИИ'МЧИВЫЙ** *книж.* — 1. начар үзләштерүчән, авыр төшенүчән; *невосприимчивый ученик* — авыр төшенүчән укучы; 2. *мед.* бирешмәүчән (авыруга).

**НЕВПОПА'Д** *нареч. разг.* — урынсыз, вакытсыз, урынсызга, тиешсезгә.

**НЕВПРИМЕ'Р** *нареч. разг.* — ...-га карaганда, (башкалар белән) чагыштыргысыз дәрәҗәдә; *невпример остальным он много работает* — ул башкаларга караганда күп эшли, ул башкалар белән чагыштыргысыз дәрәҗәдә күп эшли.

**НЕВПРОВОРО'Т** *нареч. просторечь.*— бик күп, чиксез күп, чамасыз күп.

**НЕВРАЗУМИ'ТЕЛЬНЫЙ** — аңлаешсыз, томанлы.

**НЕВРАЛГИ'Я** *ж. мед.* — невралгия (нерв авыруларының бер төре).

**НЕВРАСТЕ'НИК** *м.* — неврастеник (неврастения белән авыручы).

**НЕВРАСТЕНИ'Я** *ж.* — неврастения (нерв авыруларының бер төре).

**НЕВРЕДИ'МОСТЬ**: **в целости и невредимости** — сау-сәламәт, зыян тидермичә, җил-янгыр тидермичә.

**НЕВРЕДИ'МЫЙ** — сау-сәламәт, зыянсыз.

**НЕВРЕ'ДНЫЙ** — 1. к. безвредный; 2. *в знач. сказ.* зарарлы түгел, зыянлы түгел.

**НЕВРИ'Т** *м. мед.* — неврит (нервлар ялкынсынуы).

**НЕВРО'З** *м. мед.* — невроз (нерв системасы авыруы).

**НЕВРОЛО'ГИЯ** *науч.* — неврология (анатомиянең нервлар төзелешен өйрәнә торган бүлеге; медицинаның нерв авыруларын өйрәнә торган бүлеге).

**НЕВРОПАТО'ЛОГ** *м.* — невропатолог (нерв авыруларын дәвалаучы врач).

**НЕВРОПАТОЛО'ГИЯ** *ж.* — невропатология (медицинаның нерв авыруларын өйрәнә торган бүлеге).

**НЕВТЕРПЁЖ** *нареч. в знач. сказ. просторец.* — чыдар хәл калмады, түзәр хәл калмады; *мне невтерпёж* — минем чыдар хәлем калмады.

**НЕВЫ'ГОДА** *ж.* — зыян, зарар, файдасыз як; *учесть все выгоды и невыгоды этого дела* — бу эшнең бөтен файдалы һәм файдасыз якларын исәпкә алырга кирәк.

**НЕВЫ'ГОДНОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. файдасызлык, зарарлылык; 2. уңайсызлык; 3. ямьсезлек, күрексезлек, шыксызлык.

**НЕВЫ'ГОДНЫЙ** — 1. (*убыточный*) файдасыз, зарарлы, табышсыз; 2. (*неудобный*) уңайсыз, җайсыз. 3. (*непривлекательный*) ямьсез, күрексез, шыксыз, күңелгә ятышсыз.

**НЕВЫ'ДЕРЖАННОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. өлгермәгән булу, өлгереп җитмәү; 2. тотнаксызлык; 3. эзлексезлек.

**НЕВЫ'ДЕРЖАННЫЙ** — 1. (*не совсем готовый*) өлгермәгән, өлгереп җитмәгән, чыныкмаган; 2. тотнаксыз; *невыдержанный человек* — тотнаксыз кеше; *политически невыдержанный человек* — политик яктан тотнаксыз кеше; 3. эзлексез; *невыдержанный стиль*, — эзлексез стиль.

**НЕВЫ'ЕЗД** *м. мн.* нет, *офиц.* — бер җиргә дә китмәү.

**НЕВЫЛА'ЗНЫЙ**, *реже* **НЕВЫ'ЛАЗНЫЙ** *разг.* — 1. чыга алмаслык, ерып чыга алмаслык; 2. *перен.* котылгысыз, ерып чыга алмаслык, ерып чыккысыз. ◇ Невылазные долги — түләп бетерә алмаслык бурычлар.

**НЕВЫНОСИ'МЫЙ** — түзә алмаслык, чыдый алмаслык, чыдамаслык, бик көчле, адәм күтәрмәслек.

**НЕВЫПОЛНЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *офиц.* — үтәлмәү, тутырылмау; үтәмәү, тутырмау; *невыполнение плана* — планның үтәлмәве (тутырылмавы), планны үтәмәү (тутырмау).

**НЕВЫРАЗИ'МЫЙ** *книж.* — тел (сүз) белән әйтеп бетергесез, тел белән әйтеп бирерлек булмаган, тел белән әйтеп булмый торган, сүз белән генә аңлатырлык булмаган.

**НЕВЫСО'КИЙ** — 1. (*о человеке*) уртача буйлы; 2. (*о предметах*) биек булмаган, шактый тәбәнәк; 3. түбән; *товар невысокого качества* — түбән сыйфатлы товар; 4. начар; *быть невысокого мнения о ком-л.* — берәр кеше турында начар фикердә булу.

**НЕВЫСЫХА'ЕМЫЙ** *редко* — 1. кипми торган, кипмәс, мәңге юеш; *невысыхаемое болото* — кипми торган сазлык; 2. бертуктаусыз түгелгән, кипмәс; *смерть разом наложила бы конец ее невысыхаемым слезам* (Гончаров) — үлем аның бертуктаусыз түгелгән (кипмәс) күз яшенә берьюлы чик куяр иде.

**НЕВЫ'ХОД** *м.* — эшкә чыкмау, прогул.

**НЕВЯ'ЗКА** *ж.* — 1. *спец.* ялгышлык, сызыкларның туры килмәве (сызымда); 2. (*отсутствие связи, согласованности*) бәйләнешсезлек, бердәмлек булмау.

**НЕ'ГА** *ж. мн.* нет — 1. (*ласка, бережный уход*) иркәләү, кадерләү; 2. (*довольство*) гамьсез тормыш, рәхәт тормыш, мул тормыш, муллык, иркен тормыш; 3. *поэт.* (*блаженство, упоение*) рәхәт, рәхәтлек, хозурлык.

**НЕГА'ДАННО**: нежданно-негаданно — к. нежданно.

**НЕГА'ДАННЫЙ** *разг.*: нежданный негаданный — к. нежданный.

**НЕГАТИ'В** *м.* — негатив (фотографиядә — пыялага яки плёнкага төшерелгән кире, ягъни ак урынына кара, кара урынына ак булып төшкән рәсем; шундый рәсем төшерелгән пыяла яки плёнка).

**НЕГАТИ'ВНЫЙ** I *книж.* — тискәре; *негативный ответ* — тискәре җавап.

**НЕГАТИ'ВНЫЙ** II — негатив...-ы; *негативное стекло* — негатив пыяласы.

**НЕГАШЁНЫЙ** *тех.*: негашёная известь — сүндерелмәгән известь.

**НЕ'ГДЕ** *нареч.* — 1. *с инф.* урын юк; *негде сесть* — утырырга урын юк; 2. *разг.* (*неоткуда*) урын юк, беркайдан да ...-ып булмый; *негде взять* — алыр урын юк, беркайдан да алып булмый; 3. *устар.* (*где-то*) кайдадыр.

**НЕГЛА'СНО** *нареч.* — шыпырт кына, яшертен, мыштым гына; астыртын.

**НЕГЛА'СНЫЙ** *офиц. дореvол.* — яшерен, игълан ителмәгән.

**НЕГЛИЖЕ'** *разг. ср. нескл. устар.* — өй киеме (өйдә киелә торган җиңелчә кием). ◇ Вести себя неглиже — үзеңне иркен тоту, берни белән дә исәпләшмәү.

**НЕГЛИЖИ'РОВАТЬ** *несов. разг. устар.* — игътибарсыз карау, бернәрсә белән дә исәпләшмәү, илтифатсызлык күрсәтү.

**НЕГЛУ'ПЫЙ** *разг.* — шактый акыллы; *в знач. сказ.* ахмак түгел.

**НЕГО'ДНИК** *м.*, **НЕГО'ДНИЦА** *ж. разг. неодобр.* — әшәке, юньсез, булдыксыз.

**НЕГО'ДНОСТЬ** *ж. мн.* нет — яраксызлык, яраксыз хәл.

**НЕГО'ДНЫЙ** — 1. (*неподходящий*) яраксыз; 2. *разг.* (*низкий, бессовестный*) түбән, оятсыз, вөҗдансыз, юньсез; *негодный человек* — юньсез кеше.

**НЕГОДОВА'НИЕ** *ср. мн.* нет — нәфрәт, тирән ачу.

**НЕГОДОВА'ТЬ** *сов.* — бик нык ачулану, нәфрәтләнү.

**НЕГОДЯ'Й** *м.*, **НЕГОДЯ'ЙКА** *ж. бран.* — явыз, түбән (кеше); кабахәт, әшәке.

**НЕГОДЯ'ЙСТВО** *ср. разг. неодобр.* — түбәнлек, кабахәтлек, әшәкелек.

**НЕГО'ЖИЙ** *простореч. обл.* — 1. яраксыз; 2. *в знач. сказ.* ярамый, килешми; *так поступать тебе негоже* — болай эшләү сиңа ярамый (килешми).

**НЕГОЦИА'НТ** *м. устар.* — негоциант, эре сәүдәгәр (веруча чит дәүләтләр белән эш итүче сәүдәгәр).

**НЕГОЦИА'НТКА** *ж. устар.* — 1. к. негоциант; 2. негоциант хатыны.

**НЕГОЦИА'ЦИИ** *мн. офиц. дипл.* — дипломатик характердагы сөйләшүләр.

**НЕГО'ЦИЯ** *ж. устар.* — 1. (*торговля*) сәүдә; 2. (*сделка*) килешү.

**НЕГР** *м.* — негр.

**НЕГРА'МОТНОСТЬ** *ж. мн.* нет — грамотасызлык, укый-яза белмәү; надানлык.
**НЕГРА'МОТНЫЙ** — 1. *(не умеющий читать и писать)* грамотасыз, укый-яза белми торган, укый-яза белмәүче; 2. *(малограмотный)* надан, хаталар белән язучы; *неграмотный писарь* — надан писарь; 3. надан язылган, хата язылган, хаталары күп булган; *неграмотная рукопись* — хаталары күп булган кулъязма; 4. *(малосведущий)* надан, белемсез; белдексез, мәгълүматсыз; *политически неграмотный человек* — политик яктан надан кеше; 5. *(неискусный)* белер-белмәс эшләнгән.
**НЕГРИТЁНОК** *м.* — негр баласы.
**НЕГРИТО'С** *м.* — негритос (көньяк-көнчыгыш Азиядә яшәүче берничә этник группаның гомуми исеме).
**НЕГРИТЯ'НКА** *ж.* — негр хатын-кызы.
**НЕ'ГРЫ** *мн.* (*ед.* негр) — негрлар, негр халкы.
**НЕ'ГУС** *м.* — негус (Абиссиния патшасының титулы).
**НЕДА'ВНИЙ** — шушы арада гына булган, күптән түгел генә булган.
**НЕДА'ВНО** *нареч.* — шушы арада гына, күптән түгел генә, бая гына.
**НЕДАЛЁКИЙ** — 1. якындагы, якын; *недалёкая деревня* — якындагы авыл; *недалёкий путь* — якын юл; 2. *(глуповатый)* акылга сай, ахмаграк. ◇ **В недалёком будущем** — якын киләчәктә, якын арада, тиз арада. **В недалёком прошлом** — шушы арада гына, күптән түгел.
**НЕДАЛЕКО'**, **НЕДАЛЁКО** *нареч.* — 1. ерак ...-мау; *он еще, наверное, недалеко ушел* — ул әле ерак китмәгәндер; 2. *в знач. сказ.* ерак түгел, якын; *до дому уже недалеко* — өйгә ерак түгел инде, өйгә якын инде. ◇ **Идти недалёко (за примером)** — мисал китерүе бик җиңел, мисал эзләп ерак барасы түгел.
**НЕДАЛЕ'ЧЕ** *нареч. обл.* — к. недалеко.
**НЕДА'ЛЬНИЙ** — 1. к. недалёкий 1; 2. *(близкий по родству)* якын, якын кардәш.
**НЕДАЛЬНОВИ'ДНОСТЬ** *ж. мн.* нет — алдан күрә алмаучылык, сукырлык.
**НЕДАЛЬНОВИ'ДНЫЙ** — алдан күрә алмый торган, күзе җитми торган, алдан күрә алмаучы, сукыр.
**НЕДА'ЛЬНЫЙ** *обл.* — к. недальний.
**НЕДА'РОМ** — юкка гына ...-мау; бушка гына ...-мау, юкка гына түгел, бушка гына түгел, берәр сәбәп белән, берәр максат белән; *он заходил к нам недаром* — ул безгә юкка гына кермәгән.
**НЕДВИ'ЖИМОСТЬ** *ж. право* — күчми торган милек.
**НЕДВИ'ЖИМЫЙ** *право* — күчми торган; *недвижимое имущество* — күчми торган милек.
**НЕДВИЖИ'МЫЙ** *поэт. устар.* — хәрәкәтсез.
**НЕДВИ'ЖНЫЙ** *поэт. устар.* — к. недвижимый.
**НЕДВУСМЫ'СЛЕННЫЙ** — ачык, туптуры, ике төрле аңларга урын калмаслык итеп әйтелгән (эшләнгән).
**НЕДЕЕСПОСО'БНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — 1. юридик хокуксыз булу (юридик характерда эш йөртергә хокуксыз булу һәм үз эшләре өчен җаваплы булмау); 2. яраксызлык, эшкә яраксызлык, эшкә сәләтсезлек.
**НЕДЕЕСПОСО'БНЫЙ** *книж.* — 1. *право* юридик хокуксыз; 2. яраксыз, эшкә яраксыз, эшкә сәләтсез.
**НЕДЕЙСТВИ'ТЕЛЬНЫЙ** — 1. *(не оказывающий действия)* тәэсир итми торган, тәэсирсез, яраксыз; 2. *офиц. (не имеющий силы)* гамәлдән чыккан, көче беткән; яраксыз.
**НЕДЕЛИКА'ТНЫЙ** — 1. нәзакәтсез, тупас, дорфа; 2. әдәпсез; 3. тартынусыз.
**НЕДЕЛИ'МЫЙ** — 1. бүленми торган; *неделимый фонд колхоза* — колхозның бүленми торган фонды; 2. *мат.* бүленмәүчән; *неделимые числа* — бүленмәүчән саннар.
**НЕДЕ'ЛЬНЫЙ**: в недельный срок — бер атна эчендә; недельный срок — бер атналык срок.
**НЕДЕ'ЛЯ** *ж.* — атна. ◇ **Без году неделя** — яңа гына, күптән түгел генә.
**НЕДЕРЖА'НИЕ** *ср.* — тотмау, тота алмау; *недержание мочи* — боелыгын тота алмау (авыру).
**НЕДЁШЕВО** *нареч. разг.* — шактый кыйммәткә, шактый кыйбатка, арзан ...-мау; *я заплатил за книгу недёшево* — бу китапка мин шактый кыйбат түләдем, бу китапны мин арзан алмадым; *недёшево досталась эта работа* — бу эш миңа кыйммәткә төште, бу эш миңа арзанга төшмәде.
**НЕДИСЦИПЛИНИ'РОВАННЫЙ** — дисциплинасыз, тәртипсез.
**НЕДОБИРА'ТЬ** *несов.* — к. недобрать.
**НЕДОБО'Р** *м.* — 1. тулысынча җыймау, җыеп җиткермәү; 2. (берәр нәрсәнең) җыеп җиткерелмәгән өлеше.
**НЕДОБРА'ТЬ** *сов.* — җыеп җиткермәү, тиешеннән ким җыю, тулысынча җыймау.
**НЕДОБРОЖЕЛА'ТЕЛЬ** *м.*, **НЕДОБРОЖЕЛА'ТЕЛЬНИЦА** *ж.* — дошман, усаллык теләүче; явызлык теләүче, начар ният белән эш итүчән (кеше).
**НЕДОБРОЖЕЛА'ТЕЛЬНЫЙ** — усаллык теләүче, дошман күрүче, игелексез; явыз уйлы, начар ният белән эш итүчән.
**НЕДОБРОЖЕЛА'ТЕЛЬСТВО** *ср. мн.* нет — усаллык теләү, дошманлык тоту; явызлык теләү, явыз уйлылык, начар ниятле булу.
**НЕДОБРОКА'ЧЕСТВЕННЫЙ** — начар сыйфатлы.
**НЕДОБРОСО'ВЕСТНЫЙ** — 1. оятсыз, намуссыз, вөҗдансыз; *недобросовестный человек* — намуссыз кеше; 2. начар эшләнгән, тырышып эшләнмәгән, күңел куймыйча эшләнгән; *недобросовестная работа* — начар эшләнгән эш.
**НЕДОБРОХО'Т** *м. устар.* — к. недоброжелатель.
**НЕДОБРОХО'ТНЫЙ** *устар.* — 1. к. не-

доброжелательный; 2. (*вынужденный*) ирексездән эшләнгән, мәҗбүри.

**НЕДОБРОХО'ТСТВО** *ср. мн.* нет, *устар.*— к. недоброжелательство.

**НЕДО'БРЫЙ** — 1. (*недружелюбный*) усал, яман, явыз; 2. (*неприятный*) күңелсез; 3. *ср. в знач. сущ.* күңелсезлек; усаллык, явызлык, яманлык; *по лицу видно, что задумал недоброе* — усаллык уйлап йөргә йөзенә чыккан (йөзеннән күренеп тора); *случилось что-то недоброе* — ниндидер бер күңелсезлек булган. ◇ Недобрые люди *устар. эвф.*— юлбасарлар.

**НЕДОВЕ'РИЕ** *ср. мн.* нет — 1. (*сомнение в правдивости*) шик, шикләнү; 2. (*отсутствие доверия*) шикләнү, ышанмау; шик. ◇ **Вотум недоверия** — к. вотум.

**НЕДОВЕРНУ'ТЬ** *сов.*— борып җиткермәү.

**НЕДОВЕРНУ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— борылып җитмәү.

**НЕДОВЁРТЫВАТЬ** *несов.*— к. недовернуть.

**НЕДОВЕ'РЧИВО** *нареч.* — шик белән, шикләнеп, ышанмыйча.

**НЕДОВЕ'РЧИВОСТЬ** *ж. мн.* нет — ышанмау, ышанмаучанлык, ышанып җитмәүчәнлек, шикләнүчәнлек, шик.

**НЕДОВЕ'РЧИВЫЙ** — 1. ышанмаучан, шикләнүчән; *недоверчивый человек* — ышанмаучан кеше; 2. шикләнгән, ышанмаган, шикләнеп...; *недоверчивый взгляд* — шикләнеп карау.

**НЕДОВЕ'С** *м. мн.* нет, *спец.*— 1. к. недовесить 1; 2. ким чыгу, җитмәү; *в мешке два кило недовесу* — капчыктан ике кило ким чыкты.

**НЕДОВЕ'СИТЬ** *сов.*— 1. (*свешать неполным весом*) ким үлчәү, ким итеп үлчәү, үлчәвен тутырмау, тутырмыйча үлчәү; 2. *спец.* үлчәве ким чыгу; *этот мешок недовесил* — бу капчыкның үлчәве ким чыкты.

**НЕДОВЕ'СОК** *м. разг.*— ким үлчәүле; *мешок-недовесок* — ким үлчәүле капчык.

**НЕДОВЕ'ШИВАТЬ** *несов.*— к. недовесить 1.

**НЕДОВО'ЛЬНО** *нареч.*— ризасызлык белән, канәгатьсезлек белән, ризасызлык күрсәтеп (белдереп).

**НЕДОВО'ЛЬНЫЙ** — 1. канәгатьсез; 2. *в знач. сказ.* риза түгел, канәгать түгел.

**НЕДОВО'ЛЬСТВО** *ср. мн.* нет — ризасызлык, канәгатьсезлек.

**НЕДОВЫПОЛНЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — тутырып җиткермәү, үтәп җиткермәү.

**НЕДОВЫ'ПОЛНИТЬ** *сов.*— тутырып җиткермәү, үтәп җиткермәү, тулысынча үтәмәү.

**НЕДОВЫПОЛНЯ'ТЬ** *несов.*— к. недовыполнить.

**НЕДОВЫПОЛНЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.*— тутырып җиткерелмәү, үтәп җиткерелмәү, тулысынча үтәлмәү.

**НЕДОВЫ'ПУСК** *м. мн.* нет — чыгарып (бирeп) җиткермәү, чыгарып җиткерелмәү, планнан ким чыгару (бирү); планда күрсәтелгән саннан (күләмнән) ким чыгарылу; *недовыпуск в пять вагонов* — биш вагон чыгарып җиткерелмәде; *недовыпуск вагонов из ремонта* — вагоннарның ремонттан планда күрсәтелгән саннан ким чыгарылуы.

**НЕДОВЫ'РАБОТАТЬ** *сов.*— эшләп җиткермәү; тутырып җиткермәү.

**НЕДОВЫ'РУЧКА** *ж. мн.* нет, *разг.*— сатудан килеп җитмәгән кадәресе (план буенча көтелгән акчаның).

**НЕДОГА'ДЛИВОСТЬ** *ж. мн.* нет — сизгер булмау, тапкыр булмау, зирәк булмау, тапкыр түгеллек, зирәк (сизгер) түгеллек.

**НЕДОГА'ДЛИВЫЙ** — 1. аңсыз, тиз сизә алмый торган кеше, тупас зиһенле; 2. *в знач. сказ.* тапкыр түгел, зирәк (сизгер) түгел.

**НЕДОГЛЯДЕ'ТЬ** *сов. разг.*— 1. күрми калдыру, күреп җиткермәү, карап җиткермәү; *корректор недоглядел многих опечаток* — корректор күп кенә хаталарны күрми калдырган; 2. яхшылап карамау; *нянька недоглядела, и ребёнок упал* — бала караучы баланы яхшылап карамаган да бала егылган.

**НЕДОГЛЯ'ДЫВАТЬ** *несов. разг.*— к. недоглядеть.

**НЕДОГОВОРЁННОСТЬ** *ж.*— 1. әйтеп бетермәү, әйтеп җиткермәү, ачык итеп әйтмәү; *в его рассказе о событиях чувствовалась недоговорённость* — вакыйгалар турында сөйләгәндә аның әйтеп җиткермәве сизелеп тора иде; 2. (*отсутствие предварительной согласованности*) алдан килешеп куймау, алдан сөйләшеп куймау.

**НЕДОГРУ'З** *м. мн.* нет, *спец.*, **НЕДОГРУ'ЗКА** *ж. мн.* нет, *разг.*— 1. (*неполная нагрузка*) төяп җиткермәү, төяп җиткерелмәү; 2. (*недостаточная отправка чего-н. куда-н.*) ким җибәрү.

**НЕДОДАВА'ТЬ** *несов.*— к. недодать.

**НЕДОДАВА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— үтәлмәү, чыгарып җиткерелмәү, бирeп җиткерелмәү, ясап җиткерелмәү; ким бирелү.

**НЕДОДА'ТЬ** *сов.*— 1. чыгарып җиткермәү; бирeп җиткермәү; *завод недодал (столько-то) по плану* — завод план буенча (шулкадәр) бирeп җиткермәде; 2. ким бирү; *он недодал двух рублей* — ул ике сум ким бирде.

**НЕДОДА'ЧА** *ж. мн.* нет, *простореч.*— 1. к. недовыпуск; 2. (*неполная выдача чего-н.*) бирeп җиткермәү.

**НЕДОДЕ'Л** *м. простореч.*— к. недоделка.

**НЕДОДЕ'ЛКА** *ж. разг.*— 1. *только ед.* эшләнеп бетмәү; ахырына җиткерелмәү, кимчелекләре булу; *работа не принята из-за недоделки* — эшләнеп бетмәү сәбәпле (кимчелекләре булу сәбәпле) эш кабул ителмәде; 2. (*недоделанная часть чего-н.*) эшләнеп бетмәгән кисәк (урын); *в машине ещё много недоделок* — машинаның эшләнеп бетмәгән урыннары күп әле.

**НЕДОДЕ'РЖКА** *ж. мн.* нет, *тех. фот.*— тотып җиткермәү.

**НЕДОЕДА'ТЬ** *несов.*— ачлы-туклы яшәү.

**НЕДОЕ'СТЬ** *сов.*— ашап туймау, туйганчы ашамау.

**НЕДОЖИ'Н** *м. мн.* нет, *обл.*— 1. урып житкермәү; 2. урылмый калган урын (җир).

**НЕДОЖО'Г** *м. мн.* нет, *спец.*— 1. (*о кирпиче*) яндырып җиткерелмәү, начар яндыру, начар яндырылу; 2. (*об углях*) тулысынча янып бетмәү.

**НЕДОЗРЕ'ЛЫЙ** — җитлекмәгән, пешеп җитмәгән, өлгереп җитмәгән, яшел; *недозрелый арбуз* — өлгереп җитмәгән карбыз. ◇ **Недозрелая мысль** *перен.*— төптән уйланып җитмәгән фикер, төптән уйланылмаган фикер.

**НЕДОИ'МКА** *ж.*— недоимка (налогның срогында түләнелми калган өлеше).

**НЕДОИ'МЩИК** *м.*— налогны вакытында тулысынча түләп бетермәүче.

**НЕДОКАЗУ'ЕМЫЙ** *книж.* — 1. исбат ителмәслек; 2. *в знач. сказ.* исбат итәрлек түгел.

**НЕДОКО'РМ** *м. мн.* нет — кирәгенчә туйдырмау, начар ашату.

**НЕДОЛГА'**: **(вот) и вся недолга** *разг.*— шуның белән эш бетте дә, шуның белән эш бетте-китте.

**НЕДО'ЛГИЙ** — аз гына (вакыт)...; кыска гына (вакыт)...; *после недолгого колебания* — аз гына икеләнеп торганнан соң.

**НЕДО'ЛГО** *нареч.* — 1. аз гына, озак...-мау; *недолго пожила она на свете* — ул дөньяда озак яшәмәде (тормады); 2. *в знач. сказ.* җиңел, бар, мөмкин, бик тиз; *рассказать недолго* — сөйләп бирергә озак түгел; *и потонуть недолго* — батып китүең дә бар, батып китүең бик тиз. ◇ **Недолго думая** — күп (озак) уйлап тормастан.

**НЕДОЛГОВЕ'ЧНЫЙ** — 1. кыска, озакка сузылмый торган; *недолговечное счастье* — кыска бәхет; 2. *перен. в знач. сказ.* озакка җитми, тиз туза; *плетёная мебель недолговечна* — үреп ясалган мебель озакка җитми (тиз туза); 3. кыска гомерле, озак яшәми торган; *недолговечное растение* — озак яшәми торган үсемлек.

**НЕДОЛЁТ** *м. воен.*— (очып) барып җитмәү, житә алмау (пуля, снаряд һ. б.).

**НЕДОЛО'В** *м. мн.* нет, *спец.*— җитәрлек тотмау, тотып җиткермәү, планнан ким тоту; җитәрлек тотылмау, тотып җиткерелмәү, планнан ким тотылу; *недолов рыбы* — балыкның планнан ким тотылуы.

**НЕДОЛЮ'БЛИВАТЬ** *несов. разг.*— яратып җиткермәү, яратып бетермәү.

**НЕДО'ЛЯ** *ж. устар.*— бәхетсезлек, бәхетсез язмыш.

**НЕДОМЕ'РИВАТЬ** *несов.* — к. недомерить.

**НЕДОМЕ'РИТЬ** *сов. разг.*— ким үлчәү, үлчәп җиткермәү.

**НЕДОМЕ'РОК** *м. спец.*— үлчәве (күләме) нормаль булмаган әйбер.

**НЕДОМЕ'РЯТЬ** *сов.*— к. недомерить.

**НЕДОМОГА'НИЕ** *ср.*— хәлсезлек, кәеф китү, кәеф китеп тору, авырып тору; *во всём теле чувствовалось недомогание* — бөтен тәнемдә хәлсезлек сизелә иде; *лёгкое недомогание* — аз гына кәеф китеп тору.

**НЕДОМОГА'ТЬ** *несов. разг.*— хәлсезлек сизү, кәеф китеп тору.

**НЕДОМО'Л** *м. мн.* нет, *спец.*— начар тартылу (он турында).

**НЕДОМО'ЛВКА** *ж.*— әйтеп җиткермәү, әйтеп җиткерелмәгән фикер.

**НЕДОМЫ'СЛИЕ** *ср. книж.*— тиешенчә уйлап җиткермәү, ахмаклык, юләрлек.

**НЕДОНЕСЕ'НИЕ** *ср. офиц.*— хәбәр итмәү, белдермәү (булып үткән яки хәзерләнә торган җинаять турында хөкүмәт органнарына хәбәр итмәү).

**НЕДОНОСИ'ТЕЛЬ** *м. офиц.*— (җинаять турында) хәбәр итмәүдә гаепле кеше, белдермәүдә гаепле кеше.

**НЕДОНО'СОК** *м.*— җитлекми туган.

**НЕДООЦЕ'НИВАТЬ** *несов.*— к. недооценить.

**НЕДООЦЕ'НИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— бәя биреп җиткерелмәү, әһәмият биреп җиткерелмәү.

**НЕДООЦЕНИ'ТЬ** *сов.*— бәя биреп җиткермәү, әһәмият биреп җиткермәү.

**НЕДОПЁК** *м. мн.* нет — 1. пешереп җиткермәү, пешереп җиткерелмәү, начар пешерү; *недопёк хлеба* — икмәкне пешереп җиткермәү; 2. *спец.* ким пешереп чыгару.

**НЕДОПИВА'ТЬ** *несов. разг.*— к. недопить.

**НЕДОПИ'ТЬ** *сов. разг.*— җитәрлек эчмәү, туйганчы эчмәү.

**НЕДОПЛА'ТА** *ж.*— түләп җиткермәү, биреп бетермәү.

**НЕДОПОЛУЧА'ТЬ** *несов.*— к. недополучить.

**НЕДОПОЛУЧА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— алып бетерелмәү, ким итеп алыну.

**НЕДОПОЛУЧИ'ТЬ** *сов.*— алып бетермәү, ким алу.

**НЕДОПУСТИ'МЫЙ** — 1. юл куелмаслык, һич тә ярамый торган; 2. *в знач. сказ.* һич тә ярамый.

**НЕДОРА'ЗВИТЫЙ** — үсеп җитмәгән, үсеп җитми калган.

**НЕДОРАЗУМЕ'НИЕ** *ср.*— 1. (*ошибочное, неполное понимание*) аңлашылмау, аңлап җиткермәү, төшенеп җиткермәү, ялгышлык; 2. *разг. (спор)* бәхәс, каршылыклар; 3. (*ссора*) тавыш, талаш.

**НЕДО'РОГО** *нареч.* — арзан; *в знач. сказ.* кыйбат түгел, арзан.

**НЕДОРОГО'Й** — 1. арзанлы, арзан, арзан хаклы; 2. *в знач. сказ.* кыйбат түгел, арзан.

**НЕДОРО'Д** *м.*— к. неурожай.

**НЕ'ДОРОСЛЬ** *м.*—1. *истор.* үсеп җитмәгән, буйга җитмәгән (балигъ булмаган һәм әле дәүләт хезмәтенә кермәгән яшь дворян); 2. *перен. разг. ирон.* җитлекмәгән тинтәгрәк яшүсмер.

**НЕДОСЕ'В** *м. с.-х.*— ким чәчү.

**НЕДОСЛЫ'ШАТЬ** *сов.*— ишетеп җиткермәү, ишетми калу.

**НЕДОСМА'ТРИВАТЬ** *несов.*— к. недосмотреть.

**НЕДОСМО'ТР** *м. мн.* нет — карап җиткермәү, игътибар белән карамау, игътибарсызлык, начар карау.

**НЕДОСМОТРЕ'ТЬ** *сов.*— карап җиткермәү, күрми калу.

**НЕДОСО'Л** *м. мн.* нет — тозлап җиткермәү, тозланып җитмәү, тозы җиңел булу.

**НЕДОСПА'ТЬ** *сов.*— йоклап туймау, йокы туймау, туйганчы йокламау.

**НЕДОСТАВА'ТЬ** *несов.*— җитмәү, җитешмәү. ◇ **Этого ещё недоставало** *разг.*— шул гына җитмәгән иде.

**НЕДОСТА'ТОК** *м.*— 1. (*несовершенство, погрешность*) кимчелек, җитешсезлек; җитешсез як; 2. *только ед. (неполное колич. кого-чего-н.)* җитмәү, җитешмәү; 3. *чаще мн. разг.* мохтаҗлык, ярлылык, җитешсезлек.

**НЕДОСТА'ТОЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет —1. азлык, җитәрлек булмау; 2. канәгатьләндерерлек булмау, ризалатырлык булмау.

**НЕДОСТА'ТОЧНЫЙ** — 1. аз; *у него недостаточное количество денег* — аның акчасы аз; *в знач. сказ.* җитәрлек түгел; 2. (*неудовлетворительный*) канәгатьләндерерлек булмаган; җитәрлек булмаган; *в знач. сказ.* канәгатьләндерерлек түгел; 3. *устар. (небогатый)* ярлы; *в знач. сказ.* бай түгел.

**НЕДОСТА'ТЬ** *сов.*— к. недоставать.

**НЕДОСТА'ЧА** *ж. разг.*— җитмәү, җитешмәү (әйбернең, акчаның ким чыккан, кирәгенчә булмаган күләме, саны).

**НЕДОСТИГА'ЕМЫЙ** *книж.*— к. недостижимый.

**НЕДОСТИЖИ'МЫЙ** — 1. ирешелмәслек, ирешүе мөмкин булмаган; *недостижимая цель* — ирешелмәслек максат; 2. *в знач. сказ.* ирешерлек түгел.

**НЕДОСТО'ЙНЫЙ** — 1. тиң булмаган, лаек булмаган; *человек, недостойный похвалы* — мактауга лаек булмаган кеше; 2. *в знач сказ.* тиң түгел, лаек түгел; *я недостоин вас* — мин сезгә тиң түгел; 3. түбән, әдәпсез, килешмәгән; *недостойный человек* — түбән кеше; *недостойный поступок* — килешмәгән эш.

**НЕДОСТУ'ПНЫЙ** — 1. (*неприступный*) янына бара алмаслык, якын килә алмаслык; *в знач. сказ.* янына барырлык (килерлек) түгел; 2. (*строгий*) кырыс; 3. авыр, аңлавы кыен булган, аңлашылмаган, аңлашылмый торган; *эта книга недоступна детям* — бу китап балалар өчен авыр; 4. *разг.* бик кыйммәтле, бик тозлы; *недоступный товар* — бик кыйммәтле товар.

**НЕДОСУ'Г** *м. мн.* нет, *разг.*— 1. вакыт юклык, буш вакыт юклык; *сослались на недосуг и не пришли* — вакыт юклыкка сылтау итеп килмәделәр; 2. *в знач. сказ. с инф.* вакыт юк; *мне недосуг с тобой говорить* — синең белән сөйләшергә минем вакытым юк.

**НЕДОСУ'ЖНО** *обл.*— вакыт юк.

**НЕДОСЧИТА'ТЬСЯ** *сов.*— җитмәү, чыкмау, ким чыгу; *пастухи не досчитались двух коров* — көтүчеләрнең ике сыеры ким чыкты (җитмәде).

**НЕДОСЫПА'ТЬ** *несов.*— к. недоспать.

**НЕДОСЯГА'ЕМЫЙ** *книж.*— к. непостижимый.

**НЕДОТЁПА** *м.* и *ж. разг. фам. неодобр.*— аңгыра, җебегән, булмаган, булдыксыз, мәми авыз.

**НЕДОТРО'ГА** — 1. *м.* и *ж.* чебен тимәс чер итәр, бик тиз хәтере калучан кеше, үпкәчел кеше; 2. *ж. бот.* тидермәс, кыркынасы, мимоза.

**НЕДОУ'ЗДОК** *м.*— нукта (авызлыксыз йөгән).

**НЕДОУМЕВА'ТЬ** *несов.*— аптырау, аптырап калу, аптырашта калу; аңлап җиткермәү, аңлап җиткерә алмау.

**НЕДОУМЕ'ЛЫЙ** *разг.*— аптыраган.

**НЕДОУМЕ'НИЕ** *ср.*— шикләнү, икеләнү, аптыраш.

**НЕДОУМЕ'ННО** *нареч.*— шикләнеп, икеләнеп, аптырап.

**НЕДОУМЕ'ННЫЙ** — шикле, икеләнүле, шикләнеп..., икеләнеп..., аптырап...; *недоуменный взгляд* — аптырап карау.

**НЕДОУ'МИЕ** *ср. мн.* нет, *устар.*— аңгыралык, ахмаклык.

**НЕДОУ'МОК** *м. разг.*— аңлы-миңле кеше, аңгыра кеше.

**НЕДОУЧЁТ** *м. мн.* нет — тулысынча исәпкә алмау, исәпкә алып бетермәү.

**НЕДОУ'ЧКА** *м.* и *ж. разг.*— сай белемле, аз белемле, надан, төпле белеме булмаган, аннан-моннан гына укыган кеше.

**НЕДОХВА'Т** *м. мн.* нет, **НЕДОХВА'ТКА** *ж. простореч.*— к. недостача.

**НЕДОЧЁТ** *м.*— 1. кимлек, җитмәү; *недочёт денег* — акчаның кимлеге; 2. җитешсезлек, кимчелек, ялгышлык; *недочёты в работе* — эштәге җитешсезлекләр.

**НЕ'ДРА** *ед.* нет, *книж.*— җир асты; *нефть добывают из недр земли* — нефтьне җир астыннан табалар. ◇ **Земля, её недра, воды, леса... являются государственной собственностью, т. е. всенародным достоянием** (Конституция СССР) — җир, аның эчке байлыклары, сулар, урманнар... дәүләт милке, ягъни бөтен халык байлыгы. **В недрах души** — күңел түрендә.

**НЕДРЕ'МЛЮЩИЙ** — уяу, сизгер.

**НЕ'ДРУГ** *м. книж.*— дошман.

**НЕДРУЖЕЛЮ'БНО** *нареч.*— дошманлык белән, дошманнарча.

**НЕДРУЖЕЛЮ'БНЫЙ** — дошман..., дошманнарча..., усал; *недружелюбный взгляд* — дошманнарча карау, усал караш.

**НЕДУ'Г** *м. книж.*— авыру, хәлсезлек, кәефсезлек.

**НЕДУ'ЖИТЬСЯ** *несов. безл. обл.*— авыру, авырып тору; *недужится мне* — мин авырыйм, авырып торам (минем хәлем юк).

**НЕДУРНО'Й** — 1. шактый яхшы, яхшы гына; *в знач. сказ.* шактый яхшы, начар түгел; *голос был недурной* — тавышы шактый яхшы иде; 2. *только в краткой форме в сочетании со словом „собой" и без него* чибәр генә, матур гына, сылу гына; *она недурна собой* — ул үзе чибәр генә.

**НЕДУ'РСТВЕННЫЙ** *разг. фам.*— к. недурной.

**НЕДЮ'ЖИННЫЙ** — 1. гадәттән тыш; *не-*

*дюжинная сила* — гадәттән тыш көч; 2. башкалардан аерылып тора торган (көче, сәләте, таланты һ. б. белән); *недюжинный человек* — башкалардан (көче, сәләте, таланты яки башка ягы белән) аерылып тора торган кеше.

**НЕЕСТЕ'СТВЕННЫЙ** — 1. ясалма, табигый булмаган; 2. *в знач. сказ.* табигый түгел.

**НЕЖДА'ННО** *нареч:* **нежданно-негаданно** — көтмәгәндә.

**НЕЖДА'ННЫЙ** — көтелмәгән, очраклы.

**НЕЖЕЛА'НИЕ** *ср. мн.* нет — теләмәү.

**НЕЖЕЛА'ТЕЛЬНЫЙ** — 1. (*не соответствующий желанию*) теләмәгән, кирәкмәгән, кирәксез; 2. *книж. (неприятный, тягостный)* күңелсез, авыр; 3. *книж. (предосудительный, недопустимый)* гаеп итәрлек, ярамаган, начар.

**НЕ'ЖЕЛИ** *союз, устар.* — ...-га караганда, ...-дан. ◇ **Прежде нежели** *устар.* — ...-дан элек, ...-ганчы.

**НЕЖЕНА'ТЫЙ** — өйләнмәгән.

**НЕ'ЖЕНКА** *м.* и *ж. разг.* — иркә, назлы.

**НЕЖИВО'Й** — 1. (*мёртвый*) җансыз, үле, үлгән; 2. (*неодушевлённый*) җансыз, терек булмаган; 3. (*лишённый жизненной энергии*) сүлпән, сүрән, җансыз, җебегән.

**НЕЖИ'ЗНЕННЫЙ** *книж.* — тормышка бәйләнеше булмаган, тормыш өчен әһәмиятсез, тормыш өчен кирәге булмаган, кирәксез; *нежизненная тема* — тормышка бәйләнеше булмаган тема. ◇ **Нежизненный человек** — дөнья көтә белми торган кеше.

**НЕЖИЛО'Й** — 1. (*необитаемый*) кеше тормый торган; 2. (*не предназначенный для жилья*) кеше торыр өчен корылмаган (төзелмәгән); 3. *спец. (негодный для жилья)* торырга яраксыз, торырга ярамый торган.

**НЕ'ЖИТЬ** I *несов.* — иркәләү, назлау.

**НЕ'ЖИТЬ** II *ж. обл.* — 1. *только ед. миф.* җеннәр, шүрәлеләр, йорт иясе, су анасы һ. б.; 2. (*нежилое место*) кеше аяк басмаган җир.

**НЕ'ЖИТЬСЯ** *несов.* — иркәләнү, назлану; рәхәтләнү.

**НЕ'ЖНИЧАТЬ** *несов.* — 1. *ирон.* иркәләнү, назлану; 2. *перен. разг.* иркәләү (йомшаклык күрсәтү, ирек бирү мәгънәсендә); ...*поменьше „нежничайте“ с ликвидаторами* (Ленин) — ... ликвидаторларны азрак „иркәләгез“.

**НЕ'ЖНОСТЬ** *ж.* — 1. *только ед.* ягымлылык, мөлаемлык, йомшаклык, нәфислек; *нежность голоса* — тавышның ягымлылыгы; *нежность цветов* — чәчәкләрнең нәфислеге; 2. йомшаклык, йомшак күңеллелек; *в нежности матушкиной я не сомневался* (Пушкин) — мин әниемнең йомшак күңеллелегенә шикләнми идем; 3. *преимущ. мн. разг. (ласки, ласковые слова)* назлау сүзләре, иркәләү сүзләре, йомшак сүзләр, нәфис сүзләр; 4. *преимущ. мн. разг. пренебр.* назлылык; *что за нежности?* — бу нинди назлылык?

**НЕ'ЖНЫЙ** — 1. ягымлы, мөлаем; *нежный голос* — ягымлы тавыш; *нежный взгляд* — мөлаем караш; 2. назлы, иркә; *нежный ребёнок* — иркә бала; 3. нәфис; *нежный цвет* — нәфис төс. ◇ **Нежные чувства** — нечкә хисләр. **Нежный возраст** — сабый чак, яшь чак. **Нежный пол** *устар.* — хатын-кызлар. **Нежное здоровье** — тиз авыручан булу. **Нежное блюдо** — җиңел аш.

**НЕЗАБВЕ'ННЫЙ** *книж.* — онытылмас, онытылмаслык, мәңге онытылмаслык.

**НЕЗАБУ'ДКА** *ж. бот.* — күгәрчен күзе, күгәрченкүз, зәңгәр чәчәк, чыпчык күзе.

**НЕЗАБЫВА'ЕМЫЙ** *книж.* — онытылмаслык, онытылмас, тирән тәэсирле, тирән тәэсир калдырган; *незабываемый 1919 год* — онытылмас 1919 ел.

**НЕЗАВИ'ДНЫЙ** *разг.* — күренексез, сөйкемсез; *в знач. сказ.* начар, кызыгырлык түгел.

**НЕЗАВИ'СИМО** *нареч.* — бәйсез хәлдә, мөстәкыйль рәвештә, ирекле. ◇ **Независимо от...** *книж.* — ...-га карамастан.

**НЕЗАВИ'СИМОСТЬ** *ж. мн.* нет — бәйсезлек, мөстәкыйльлек.

**НЕЗАВИ'СИМЫЙ** — 1. бәйсез, ирекле, мөстәкыйль: *независимые страны* — бәйсез (ирекле) илләр; 2. ирекле, буйсынмаучан; *независимый характер* — буйсынмаучан характер.

**НЕЗАВИ'СЯЩИЙ: по независящим от нас обстоятельствам** — бездән булмаган (безгә бәйләнмәгән) сәбәпләр (хәлләр) аркасында.

**НЕЗАДА'ЧА** *ж. разг.* — уңышсызлык, эш уңмау.

**НЕЗАДА'ЧЛИВЫЙ** *разг.* — 1. уңышсыз; *незадачливый день* — уңышсыз көн; 2. беркатлы, эше пешми торган; *незадачливый парень* — беркатлы егет, эше пешми торган егет.

**НЕЗАДО'ЛГО** *нареч. (с предлогами „до“ или „перед“)* — ...-дан аз гына алданрак, ...-дан борынрак, ...-дан аз гына элегрәк, ...-дан аз гына элек; *незадолго перед революцией* — революциядән аз гына алданрак.

**НЕЗАКОННОРОЖДЁННЫЙ** *доревол. офиц.* — никахсыз туган, уйнаштан туган, законсыз бала (закон буенча бертөрле дә хокуклары булмаган бала).

**НЕЗАКО'ННЫЙ** — законсыз, законга каршы булган, законнан тыш эшләнгән, законга сыймый торган. ◇ **Незаконный брак** *доревол.* — никахсыз өйләнешү. **Незаконный ребёнок** — к. незаконнорождённый.

**НЕЗАМЕДЛИ'ТЕЛЬНО** *нареч.* — тоткарсыз, тиз генә, тиз вакытта, тиз арада, кичекмәстән, тиз вакыт эчендә.

**НЕЗАМЕДЛИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.* — тоткарсыз, тиз, тиз вакыт эчендә..., тиз арада...; *незамедлительный ответ* — тоткарсыз җавап бирү, тиз вакыт эчендә җавап бирү.

**НЕЗАМЕНИ'МЫЙ** — алмаштыргысыз, бик кирәкле, алмашы юк.

**НЕЗАМЕ'ТНО** *нареч.* — сиздермичә, си-

зелмәслек итеп, беленмәслек итеп, сизелмичә, беленмичә.

**НЕЗАМЕ'ТНЫЙ** — сизелмәслек, беленмәслек, күзгә күренмәслек; сизелми торган, беленми торган, күзгә ташланмый торган.

**НЕЗАМО'ЖНИК** *м. устар.*—ярлы крестьян (Украинада).

**НЕЗАМО'ЖНЫЙ** — ярлы; *незаможный крестьянин* — ярлы крестьян.

**НЕЗАМУ'ЖНЯЯ** — иргә бармаган, кияүгә чыкмаган.

**НЕЗАМЫСЛОВА'ТЫЙ** *разг.*— 1. бик гади; 2. *шутл.* беркатлы; *незамысловатый человек* — беркатлы кеше.

**НЕЗАПА'МЯТНЫЙ** *книж.*— 1. бик күптәнге, бик борынгы; 2. *редко* к. незабвенный, незабываемый.

**НЕЗАПЯ'ТНАННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— сафлык, керсезлек.

**НЕЗАПЯ'ТНАННЫЙ** *книж.* — тапсыз, тапланмаган, тап төшмәгән, керсез; гаепсез.

**НЕЗАСЕ'ЯННЫЙ** — чәчелми калган, кысыр калган; *незасеянное поле* — кысыр калган басу.

**НЕЗАСЛУ'ЖЕННО** *нареч.* — тиешсезгә, урынсызга, гаепсезгә, нахакка, бер дә юкка.

**НЕЗАСЛУ'ЖЕННЫЙ** — тиешсез, урынсыз.

**НЕЗАТЕ'ЙЛИВЫЙ** *разг.* — гади, артык катлаулы булмаган; *в знач. сказ.* гади, артык катлаулы түгел.

**НЕЗАУРЯ'ДНЫЙ** — гадәттән тыш зур, башкалардан аерылып тора торган; *незаурядные способности* — гадәттән тыш (зур) сәләт.

**НЕ'ЗАЧЕМ** *нареч. разг.* — кирәге юк, мәгънәсе юк; *незачем ходить туда* — анда баруның кирәге (мәгънәсе) юк.

**НЕЗВА'НЫЙ** — чакырылмаган, чакырусыз килгән, чакырмыйча килгән, чакырылмыйча килгән.

**НЕЗДЕ'ШНИЙ** *разг.*— читтән килгән (кеше), килмешәк; *в знач. сказ.* мондагы түгел, читтән килгән (кеше); *он человек нездешний* — ул мондагы кеше түгел, ул читтән килгән кеше. ◇ Нездешний мир *книж. устар.*— теге дөнья.

**НЕЗДОРО'ВИТЬСЯ** *несов. безл.*: мне нездоровится — кәефем юк, хәлем юк, авырып торам; ему нездоровится — ул авырып тора, аның кәефе юк.

**НЕЗДОРО'ВЫЙ** — 1. авыру, чирле; *нездоровый организм* — авыру организм; 2. саулыкка зарарлы, саулык өчен зарарлы; *нездоровый климат* — саулык өчен зарарлы климат; 3. *в знач. сказ.* сау түгел, авыру; *он сегодня нездоров* — ул бүген авыру, ул бүген сау түгел; 4. зарарлы; начар; *нездоровое воспитание* — начар тәрбия.

**НЕЗДОРО'ВЬЕ** *ср. мн.* нет — сәламәтсезлек, хәлсезлек.

**НЕЗЛО'БИ'ВОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж. устар.*— әчкерсезлек, йомшак күңеллелек, шәфкатьлелек.

**НЕЗЛО'БИ'ВЫЙ** *книж. устар.*— әчкерсез, йомшак күңелле, шәфкатьле.

**НЕЗЛО'БИЕ** *ср. мн.* нет, *устар.*— к. незлобивость.

**НЕЗНА'ЕМО** *нареч. обл.*— к. неведомо.

**НЕЗНАКО'МЕЦ** *м.*, **НЕЗНАКО'МКА** *ж.*— белмәгән кеше, таныш булмаган кеше, ят кеше.

**НЕЗНАКО'МСТВО** *ср. мн.* нет — таныш булмау, белмәү.

**НЕЗНАКО'МЫЙ** — 1. ят, белмәгән, таныш булмаган; *незнакомые места* — белмәгән җирләр; 2. *в знач. сказ.* таныш түгел, ят; 3. *в знач. сущ.* белмәгән кеше, таныш булмаган кеше, ят кеше.

**НЕЗНА'МО** *нареч. обл.*— к. незнаемо.

**НЕЗНА'НИЕ** *ср. мн.* нет — белмәү, хәбәрдар булмау.

**НЕЗНА'ЧАЩИЙ** — әһәмиятсез, буш.

**НЕЗНАЧИ'ТЕЛЬНЫЙ** — 1. әһәмиятсез, әһәмияте булмаган, исәпкә алынмаслык, игътибар итмәслек, кечкенә; *незначительная причина*—кечкенә сәбәп, исәпкә алынмаслык сәбәп; 2. кечкенә, аз; *незначительная сумма* — кечкенә сумма; 3. *разг.* (*о человеке*) авторитетсыз, кечкенә, сүзе үтми торган.

**НЕЗРЕ'ЛЫЙ** — 1. пешмәгән, пешеп җитмәгән, өлгермәгән; *незрелое яблоко* — өлгермәгән алма; 2. *перен.* җитлекмәгән, чиле-пешле; *незрелый перевод*—чиле-пешле тәрҗемә.

**НЕЗРИ'МЫЙ** *книж. поэт.*— 1. (*незаметный, невидимый*) сизелмәслек, беленмәслек, күзгә күренмәслек; сизелми торган, беленми торган, күзгә күренми торган; 2. (*таинственный, непостижимый*) яшерен, серле, күзгә күренми торган.

**НЕЗЫ'БЛЕМЫЙ** *книж.*— 1. нык, каты, тотрыклы; *незыблемая почва* — каты җир; 2. *перен.* какшамас, җимерелмәс; *незыблемая основа* — какшамас нигез.

**НЕИЗБЕ'ЖНО** *нареч.*— котылгысыз рәвештә.

**НЕИЗБЕ'ЖНОСТЬ** *ж. мн.* нет — котылгысызлык.

**НЕИЗБЕ'ЖНЫЙ** — котылгысыз.

**НЕИЗБЫ'ВНЫЙ** *книж. поэт. устар.* — онытылмас, онытылмый торган, бетми торган; *неизбывная печаль* — онытылмый торган кайгы.

**НЕИЗВЕ'ДАННЫЙ** *книж.*— 1. (*неиспытанный*) сыналмаган, беленмәгән; 2. (*неизученный*) тикшерелмәгән, өйрәнелмәгән.

**НЕИЗВЕ'СТНОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. билгесезлек, билгеле булмау, таныш булмау; 2. танылмаган булу, күренексез булу; 3. хәбәрсезлек, мәгълүматсызлык.

**НЕИЗВЕ'СТНЫЙ** — 1. билгесез, билгеле булмаган; таныш булмаган, белмәгән, ят; *какой-то неизвестный человек* — ниндидер бер белмәгән (ят) кеше; *астрономом открыта звезда, ранее неизвестная* — астроном элек билгеле булмаган йолдызны ачкан; 2. танылмаган, күренексез; *неизвестный писатель* — танылмаган язучы; 3. *в знач. сущ.* ят кеше, кем икәне билгеле

булмаган кеше, белмәгән кеше; 4. *в знач. сказ.* билгеле түгел, таныш түгел, ят, билгесез. ◇ Неизвестно кто (что, когда, где и т. д.) — белмим кем (нәрсә, кайчан, кайда һ. б.).

**НЕИЗВЕ'СТНОЕ** — 1. *мат.* билгесез сан; 2. *филос.* билгесез нәрсә.

**НЕИЗГЛАДИ'МЫЙ** *книж.* — онытылмаслык, хәтердән чыкмаслык, тирән.

**НЕИЗЛЕЧИ'МЫЙ** — дәвалап терелтүе мөмкин булмаган, дәвалап савыктыруы мөмкин булмаган, терелүе мөмкин булмаган, терелми торган. ◇ Неизлечимая болезнь — бетми торган авыру.

**НЕИЗМЕ'ННЫЙ** — 1. *книж. (не подвергающийся изменениям)* үзгәрми торган, үзгәртелми торган, даими; 2. *(обычный)* һәрвакыттагы, гадәттәге; 3. чын, ышанычлы, туры; *неизменный друг* — чын дус.

**НЕИЗМЕРИ'МО** *нареч. книж.* — чагыштыргысыз дәрәҗәдә; *неизмеримо больше* — чагыштыргысыз дәрәҗәдә күбрәк.

**НЕИЗМЕРИ'МЫЙ** *книж.* — чагыштыргысыз, бик зур, үлчәп бетерә алмаслык, иксез-чиксез; *неизмеримые степи* — иксез-чиксез далалар.

**НЕИЗЪЯСНИ'МЫЙ** *книж.* — аңлатып бирә алмаслык, аңлатып булмый торган, аңлатылмаслык.

**НЕИМЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж. канц.* — юклык, булмау; *за неимением денег* — акча булмау сәбәпле.

**НЕИМОВЕ'РНО** *нареч.* — чиктән тыш, гадәттән тыш.

**НЕИМОВЕ'РНЫЙ** — чиктән тыш зур, гадәттән тыш зур, чиктән тыш күп, гадәттән тыш күп, кеше ышанмаслык зур, кеше ышанмаслык күп.

**НЕИМУ'ЩИЙ** *книж.* — ярлы, фәкыйрь, мохтаҗлыкта яшәүче.

**НЕИНТЕРЕ'СНЫЙ** — кызыксыз, күңелсез; *в знач. сказ.* кызыклы түгел, кызыксыз, күңелсез.

**НЕИСКОРЕНИ'МЫЙ** *книж.* — нык урнашкан, нык тамыр җәйгән, төзәтүе кыен булган.

**НЕИ'СКРЕННИЙ** — 1. чын күңелдән...-маган, саф күңелдән ...-маган; *неискренний ответ* — чын күңелдән бирелмәгән җавап; 2. *(о человеке)* эчкерле, икейөзле.

**НЕИСПОВЕДИ'МЫЙ** *устар.* — билгесез, акыл ирешмәслек.

**НЕИСПОЛНЕ'НИЕ** *ср. офиц.* — үтәмәү.

**НЕИСПОЛНИ'МЫЙ** — үти алмаслык, үтәлмәслек, үтәлә алмаслык, үтәлүе мөмкин булмаган.

**НЕИСПРА'ВНОСТЬ** *ж.* — 1. *только ед.* ватыклык, бозык булу; *неисправность радиоприёмника* — радиоалгычның ватыклыгы, бозык булуы; 2. кимчелек, зарарлану; *никаких неисправностей не обнаружено* — бертөрле дә кимчелек табылмады.

**НЕИСПРА'ВНЫЙ** — 1. *(неаккуратный, нестарательный)* игътибарсыз, вакытында ...-маучы; тырыш булмаган; *в знач. сказ.* тырыш түгел; 2. ватык, бозык, яраксыз; *неисправная машина* — ватык машина; 3. таркау, тәртипсез, юлга салынмаган; *неисправное хозяйство* — юлга салынмаган (таркау) хуҗалык.

**НЕИССЯКА'ЕМЫЙ** *книж.* — бетмәс, беткесез, бетмәс-төкәнмәс, чиктән тыш күп (зур).

**НЕИ'СТОВСТВОВАТЬ** *несов. книж.* — котырыну, ярсу, дулау, җәнҗал чыгару, җәнҗал куптару, ду килү.

**НЕИ'СТОВО** — котырынып, ярсып.

**НЕИ'СТОВЫЙ** — 1. ярсулы, котырынкы; 2. ярсып..., ярсый-ярсый...; *неистовый плач* — ярсып елау.

**НЕИСТОЩИ'МЫЙ** *книж.* — беткесез, бетмәс, бетмәс-төкәнмәс, чиксез күп, иксез-чиксез.

**НЕИСТРЕБИ'МЫЙ** *книж.* — бетерә алмаслык, бетмәс, кырып бетергесез, кырып бетерә алмаслык.

**НЕИСХО'ДНЫЙ** *книж. устар.* — к. безысходный.

**НЕИСЦЕЛИ'МЫЙ** *книж. устар.* — к. неизлечимый.

**НЕИСЧЕРПА'ЕМЫЙ** *книж.* — к. неистощимый.

**НЕИСЧИСЛИ'МЫЙ** *книж.* — санап бетергесез, исәпсез күп, исәпсез-хисапсыз.

**НЕЙМЁТ**: хоть видит око, да зуб неймёт — күзең күрсә дә тешең үтми.

**НЕЙМЁТСЯ** *несов. безл. простореч.* — 1. һич тә тик тормый; *ребёнку неймётся — всё бегает* — бала һич тә тик тормый, һаман йөгерә; 2. ...-сы килә; *ему неймётся поскорее уехать* — аның тиз генә китәсе килә.

**НЕЙРОЛОГИ'ЧЕСКИЙ** — к. неврологический.

**НЕЙРОЛО'ГИЯ** — к. неврология.

**НЕЙРО'Н** *м.* — нерв күзәнәге.

**НЕЙТИ'** *несов.* — бармау; килешмәү.

**НЕЙТРАЛИЗА'ЦИЯ** *ж.* — 1. нейтральләштерү, нейтрализацияләү, нейтрализовать итү (а. *хим.* селте тәэсирендә эремәнең кислоталык сыйфатларын яки, киресенчә, кислота тәэсирендә селтелек сыйфатларын бетерү; б. *полит.* сугыш вакытында дәүләтне сугышучыларның берсе яклы да түгел дип игълан итү, битарафлаштыру); 2. *книж.* бетерү, кисү, өзү, чик кую; *нейтрализация чьего-нибудь влияния* — кемнең дә булса йогынтысына чик кую.

**НЕЙТРАЛИЗОВА'ТЬ** *сов.* и *несов.* — к. нейтрализация.

**НЕЙТРАЛИТЕ'Т** *м.* — 1. нейтралитет, катнашмау, катнашмаучылык, бер якка да катнашмау; 2. *книж.* катышмаучылык.

**НЕЙТРА'ЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет — нейтральлек, нейтраль булу, бер якка да катнашмау, битарафлык.

**НЕЙТРА'ЛЬНЫЙ** — 1. *хим.* нейтраль (әчетү яки селтеләү реакциясе бирми торган); *нейтральный раствор* — нейтраль

эремә; 2. нейтраль, битараф, катнашмаучы; *нейтральное государство* — нейтраль дәүләт.

**НЕКАЗИ'СТЫЙ** *разг.*— күренексез, ямьсез, күрексез, шыксыз, килбәтсез.

**НЕ'КАТЬ** *несов. простореч. фам.*— юкюк дип тору, баш тарту, тану, кире кагу.

**НЕКВАЛИФИЦИ'РОВАННЫЙ** — 1. квалификациясез, квалификациясе булмаган; *неквалифицированный рабочий* — квалификациясез эшче; 2. махсус хәзерләнүне сорамый торган, махсус хәзерлекне таләп итми торган, белем сорамый торган; *неквалифицированный труд*— махсус хәзерләнүне таләп итми торган хезмәт.

**НЕ'КИЙ** *местоим.*— ниндидер бер; *вас спрашивал некий Петров* — сезне ниндидер бер Петров дигән кеше сорап килгән иде.

**НЕ'КОГДА** I *нареч.*— вакыт юк; *работай, некогда разговаривать* — эшлә, сөйләшергә вакыт юк; *мне некогда* — минем вакытым юк.

**НЕ'КОГДА** II *нареч. книж.*— 1. *(в далёком прошлом)* кайчандыр, әллә кайчан, бик күптән; 2. *редко (в отдалённом будущем)* кайчан да булса, киләчәктә.

**НЕ'КОГО** (некому, некем, не с кем, не о ком) *местоим. с инф.*— ...-лык кеше юк, ...ырга кеше юк, ...-р кеше юк; *некого послать* — җибәрерлек кеше юк, җибәрер кеше юк; *некому дать* — бирер(лек) кеше юк; *некем заменить* — алмаштырырлык (алмаштырырга) кеше юк.

**НЕКОЛЕБИ'МЫЙ** *книж.*— к. непоколебимый.

**НЕКОМПЕТЕ'НТНОСТЬ** *ж. мн.* нет — белемсезлек, мәгълүматсызлык, тәҗрибәсезлек, эш белән таныш булмау.

**НЕКОМПЕТЕ'НТНЫЙ** — (эш белән) таныш булмаган; белемсез, мәгълүматсыз, тәҗрибәсез; *в знач. сказ.* таныш түгел.

**НЕКОМПЛЕ'КТНЫЙ** *офиц.*— комплектсыз, тулы комплектлы итеп эшләнмәгән.

**НЕКОРРЕ'КТНОСТЬ** *ж.* — 1. тупаслык, әдәпсезлек; 2. тупас мөгамәлә.

**НЕКОРРЕ'КТНЫЙ** — 1. *(невежливый, грубый)* тупас, әдәпсез; 2. *шахм.* ялгыш.

**НЕ'КОТОРЫЙ** *местоим.* — 1. кайбер; *некоторые деревья засохли* — кайбер агачлар корыган; 2. беркадәр, берникадәр, берничә; *некоторое время*—берникадәр вакыт; 3. *в знач. сущ. только мн.* кайберәүләр, кайбер кешеләр.

**НЕКРАСИ'ВЫЙ** — ямьсез, килбәтсез, шыксыз, күрексез, иләмсез; *в знач. сказ.* матур түгел, ямьсез, шыксыз.

**НЕКРОЛО'Г** *м.*— некролог (кемнең дә булса үлүе уңае белән аның тормышы һәм эшчәнлеге турында язылган мәкалә).

**НЕКРОЛО'ГИЯ** *ж. книж. устар.*— к. некролог.

**НЕКРО'ПОЛЬ** *м. книж. истор.*— некрополь (борынгы грекларда — зур зират, каберлек).

**НЕКРЫ'ТЫЙ** — түбәсе ябмаган, ачык, түбәсез.

**НЕКСТА'ТИ** *нареч.*— 1. вакытсыз; *пришёл некстати* — вакытсыз килде; 2. урынсыз; *он сказал это некстати* — ул моны урынсыз әйтте.

**НЕ'КТАР** и **НЕКТА'Р** *м. мн.* нет — 1. нектар (а. *книж.* грек мифологиясендә— аллаларга мәңге яшәү көче бирә торган эчемлек; б. *бот.* чәчәктәге баллы сыекча); 2. *поэт. устар.* ширбәт.

**НЕКТА'РИЙ** *м.*, **НЕКТА'РНИК** *м. бот.*— нектарник (чәчәкнең нектар чыгара торган органы).

**НЕ'КТО** *местоим.* — 1. берәү, кемдер, бер кеше; 2. *в сочетании с фамилией* дигән бер кеше; *здесь жил некто Васильев* — биредә Васильев дигән бер кеше торган.

**НЕ'КУДА** *нареч.*— һичкая...-ыр урын юк, ...-ыр урын юк, ...-ыр җир юк; *некуда пойти* — барыр җир юк; һичкая барыр урын юк; *мне некуда положить* — куяр урыным юк, һичкая куяр урыным юк.

**НЕКУЛЬТУ'РНО** *нареч.*— тупас, дорфа.

**НЕКУЛЬТУ'РНЫЙ** — 1. *(отсталый в культурном отношении)* культурасыз, культура ягыннан артта калган; 2. *бот. (не культивированный)* культуралаштырылмаган; 3. *(грубый)* тупас, дорфа.

**НЕЛА'ДНЫЙ** *разг.*— 1. *обл. (неуклюжий, нескладный)* шыксыз, ямьсез, килбәтсез; 2. *разг. неодобр.* рәтсез, юньсез; *неладный парень* — юньсез егет; 3. начар, шәптән түгел; *у него со здоровьем неладно* — аның сәламәтлеге шәптән түгел. ◇ **Будь он (она, оно) неладен** *разг.*— каһәр суккыры. **Произошло что-то неладное** — ниндидер бер күңелсезлек булган (килеп чыккан).

**НЕЛАДЫ'** *разг. ед.* нет — ызгыш, чуалыш, орыш-талаш, җәнҗал, тынышмау, тыныша алмау.

**НЕЛЕГА'ЛЬНЫЙ** —легаль булмаган, яшерен.

**НЕЛЕГА'ЛЬЩИНА** *ж. разг.* — яшерен (рөхсәтсез) басылган әдәбият; легаль булмаган эш, яшерен башкарылган эш.

**НЕЛЁГКАЯ:** **нелёгкая несёт (занесла, принесла, дёрнула и т. п.)** *фам. неодобр. укор.*— пычагыма кирәкме, пычагыма кирәк идеме, шайтаныма кирәкме.

**НЕЛЁГКИЙ** — шактый авыр, шактый кыен; *в знач. сказ.* җиңел түгел, шактый кыен, шактый авыр.

**НЕЛЕ'ПИЦА** *ж. разг.* — к. нелепость 2.

**НЕЛЕ'ПОСТЬ** *ж.*— 1. мәгънәсезлек, тозсызлык; 2. мәгънәсез сүз (эш, кыланыш), тозсыз сүз (эш, кыланыш).

**НЕЛЕ'ПЫЙ** — 1. ятышсыз, мәгънәсез, тозсыз, килделе-киттеле; *нелепое понятие*—ятышсыз бер төшенчә; 2. *разг.* рәтсез, ямьсез, килешсез; *нелепый костюм* — килешсез костюм.

**НЕЛЕ'СТНЫЙ** — начар; *быть нелестного мнения о ком-н.*— берәр кеше турында начар фикердә булу.

**НЕЛИКВИ'ДНЫЙ** *офиц.*— кыен реализацияләнә торган (мәсәлән, фонд).

**НЕЛИЦЕПРИЯ'ТНЫЙ** *книж. устар.* — гадел, турылыклы.

**НЕЛИ'ШНЕ** *нареч. в знач. сказ. разг.* — артык булмас, ...-ның зарары булмас; *нелишне будет сказать об этом* — бу турыда әйтү артык булмас, моның турында әйтүнең зарары булмас.

**НЕЛИ'ШНИЙ** *разг.* — кирәкле, урынлы; *в знач. сказ.* артык түгел, кирәкле, урынлы.

**НЕЛО'ВКИЙ** — **1.** *(неуклюжий, неумелый)* авыр сеякле, унмаган; **2.** *(неудобный)* уңайсыз, җайсыз, ипсез; **3.** *перен.* килешмәгән, уңышсыз; *неловкий поступок* — килешмәгән кыланыш; *неловкий ответ* — урынсыз җавап; **4.** *перен.* уңайсыз; *оказаться в неловком положении* — уңайсыз хәлдә калу.

**НЕЛО'ВКО** *нареч.* — уңайсыз, җайсыз, ипсез; *ему неловко об этом сказать* — аңа бу турыда әйтүе уңайсыз.

**НЕЛО'ВКОСТЬ** *ж.* — **1.** уңайсызлык; **2.** авыр сеяклелек; **3.** килешмәгән эш. ◇ **Почувствовать неловкость** — оялып, уңайсызланып китү.

**НЕЛОГИ'ЧНЫЙ** — әзлексез, бәйләнешсез, логикасыз, каршылыклы.

**НЕЛЬЗЯ'** *нареч.* — ярамый. ◇ **С этим нельзя не согласиться** — моның белән килешергә туры килә, моның белән килешми булмый, моның белән килешми мөмкин түгел. **Нельзя ли** — мөмкин булмасмы, ярамасмы. **Нельзя сказать, чтобы** *книж.* — дип әйтеп булмый. **(Как) нельзя** — бик...; *устроились на новой квартире, как нельзя лучше* — яңа квартирага бик яхшы урнаштык.

**НЕ'ЛЬМА** *ж.* — нельма (балык).

**НЕЛЮБЕ'ЗНО** *нареч.* — **1.** караңгы чырай белән; **2.** каты, тупас.

**НЕЛЮБЕ'ЗНЫЙ** — **1.** караңгы чырайлы, ягымсыз; *нелюбезный человек* — караңгы чырайлы кеше; **2.** караңгы чырай белән...; *нелюбезный приём* — караңгы чырай белән каршы алу; **3.** тупас; *нелюбезный ответ* — тупас җавап.

**НЕЛЮБИ'МЫЙ** — сөймәгән, яратмаган, читкә кагыла торган.

**НЕЛЮ'БО** *нареч. в знач. сказ.* — ошамый; *нелюбо — не слушай* — ошамаса тыңлама.

**НЕЛЮБО'ВЬ** *ж. мн.* нет — яратмау, сөймәү, күрә алмау; *нелюбовь к музыке* — музыканы яратмау.

**НЕЛЮБО'Й, НЕЛЮ'БЫЙ** *обл.* — к. нелюбимый.

**НЕ'ЛЮДИ** *простореч.* — түбән кешеләр, начар кешеләр.

**НЕЛЮДИ'М** *м.*, **НЕЛЮДИ'МКА** *ж.* — кыргый, төмсә, кешедән качучы, кешеләр белән аралашмаучан.

**НЕЛЮДИ'МЫЙ** — **1.** кыргый, ялгызлыкны яратучан, кешедән качучы, кешеләр белән аралашмаучан; *нелюдимый человек* — кыргый (кешеләр белән аралашмаучан) кеше; **2.** *устар. (пустынный)* тын, тыныч, аулак, кешесез.

**НЕМА'** *в знач. сказ. разг. шутл.* — юк.

**НЕМА'ЛО** *нареч.* — шактый күп, байтак кына, җитәрлек, аз ...-мау; *немало денег потратил* — аз акча бетермәде, шактый күп акча бетерде.

**НЕМАЛОВА'ЖНЫЙ** — шактый әһәмиятле, яхшы ук әһәмиятле.

**НЕМА'ЛЫЙ** — зур, шактый күп; *истратил немалые деньги* — шактый күп акча бетерде.

**НЕМА'РКИЙ** — кер күтәрә торган.

**НЕМЕ'ДЛЕННО** *нареч.* — ашыгыч рәвештә, тоткарсыз рәвештә, кичектерүсез, кичектермичә, хәзер үк, тиз вакытта, тиз арада, тиз, шунда ук.

**НЕМЕ'ДЛЕННЫЙ** — тоткарсыз, ашыгыч, кичектерүсез, тиз.

**НЕМЕ'ДЛЯ** *нареч. устар.* — к. немедленно.

**НЕМЕЗИ'ДА** *ж. книж.* — **1.** *(отмщение)* үч, җәза; **2.** *(неизбежная судьба)* котылгысыз язмыш.

**НЕМЕ'ТЬ** *несов.* — **1.** телдән язу, телдән калу; *больной немеет* — авыру телдән яза; **2.** кермәкләнү, бәйләнү, карышу; *язык мой немеет* — телем кермәкләнә; **3.** *перен.* тынсыз калу, тынып калу, телсез катып калу, бер сүз әйтә алмау; *неметь от восторга* — шатлыктан телсез катып калу; **4.** *перен.* *(цепенеть)* оюы.

**НЕМЕ'ЦКИЙ** — немец...-ы; *немецкий язык* — немец теле. ◇ **Немецкое платье** *просторечь. устар.* — шәһәр киеме; *одеться в немецкое платье* — шәһәрчә киенү.

**НЕМИЛОСЕ'РДНЫЙ** — **1.** *книж. устар.* *(чуждый милосердия)* рәхимсез, мәрхәмәтсез, шәфкатьсез, аяусыз, кансыз, каты күңелле; **2.** *перен. разг. (очень сильный, чрезмерный)* бик каты, гадәттән тыш каты.

**НЕМИ'ЛОСТИВЫЙ** — к. немилосердный 1.

**НЕМИ'ЛОСТЬ** *ж.* — каһәр, яратмау; начар караш.

**НЕМИ'ЛЫЙ** *разг.* — яратмаган, күңелгә ятмаган, күңелгә ошамый торган.

**НЕМИНУ'ЕМЫЙ** — котылгысыз.

**НЕМИНУ'ЧИЙ** *просторечь. нар.-поэт.* — к. неминуемый.

**НЕ'МКА** *ж.* — немец хатын-кызы.

**НЕМНО'ГИЙ** — **1.** кайбер; *в немногих странах* — кайбер илләрдә; **2.** *в знач. сущ. только мн.* кайберәүләр генә, аерым кешеләр генә. ◇ **За немногим (дело стало)** — эш кечкенәдә калды. **В немногих словах** — берничә сүз белән генә.

**НЕМНО'ГО** *нареч. разг.* — **1.** бераз гына, аз гына; күп...-мау; *времени осталось немного* — вакыт аз калды, вакыт күп калмады; **2.** *в знач. сказ.* күп түгел, аз.

**НЕМНОГОСЛО'ВНЫЙ** *книж.* — кыска, аз сүзле; *ответ был немногословен* — җавап кыска иде; *немногословный человек* — аз сүзле кеше.

**НЕМНО'ЖЕЧКО, НЕМНО'ЖКО** *нареч. разг.* — к. немного.

**НЕМО'ЖЕТСЯ** *несов. безл. разг.* — к. нездоровиться.

**НЕМО'ЖНО** *нареч. устар.* — ярамый.

**НЕМО'Й** — **1.** телсез; *немой от рожде-*

*ния* — тумыштан телсез; 2. *перен.* тын, тыныч, тып-тын, тулы; *немая ночь* — тып-тын төн; *немая тишина* — тулы тынлык (шылт иткән тавыш та юк); 3. *книж.* яшерен, эчке; *немая печаль* — яшерен (эчке) кайгы; 4. *в знач. сущ.* телсез кеше. ◇ Немая карта *геогр.* — сукыр карта, контур карта (географик исемнәр язылмаган карта). Великий немой *книж.* *ритор.* — тавышсыз кино. Нем, как рыба, или нем, как могила — сер сыя торган кеше.

**НЕМОЛОДО'Й** — урта яшьтәге, урта яшьләрдәге; 2. *в знач. сказ.* яшь түгел.

**НЕМО'ЛЧНЫЙ** *поэт.* — туктаусыз янгырый торган.

**НЕМОТА'** *ж. мн.* нет, *книж.* — 1. телсезлек; 2. *перен.* тынлык, тынычлык.

**НЕМО'ТСТВОВАТЬ** *несов. поэт. устар.* — к. безмолвствовать.

**НЕ'МОЧЬ** *ж. простореч.* — авыру, хәлсезлек. ◇ Бледная немочь — аз канлылык (хатын-кызларда була торган авыру).

**НЕМОЩНО'Й** *разг.*, **НЕ'МОЩНЫЙ** *книж.* — хәлсез, көчсез, бетерешкән, көчтән тайган.

**НЕ'МОЩЬ** *ж. разг.* — 1. *только ед.* (*слабость*) хәлсезлек, бетерешкәнлек; 2. (*болезнь*) авыру.

**НЕМУДРЁНЫЙ** *разг.* — 1. гади, җиңел; *немудрёная задача* — җиңел мәсьәлә; 2. *фам. ирон.* (*о человеке*) беркатлы; 3. *в знач. сказ. с инф.* бик табигый, бик җиңел; *немудрено и захворать* — авырып китүе дә бик җиңел.

**НЕМУ'ДРЫЙ** *разг.* — к. немудрёный 1, 2.

**НЕМУДРЯ'ЩИЙ** *простореч.* — к. немудрёный 1, 2.

**НЕМУЗЫКА'ЛЬНЫЙ** — моңсыз, аһәңсез.

**НЕ'МЦЫ** *мн.* (*ед.* немец) — немецлар, немец халкы.

**НЕМЫ'СЛИМЫЙ** *разг.* — 1. акылга сыймаслык, булуы мөмкин булмаган, кеше ышанмаслык; 2. *в знач. сказ.* мөмкин түгел, ярамый.

**НЕНАВИ'ДЕТЬ** *несов.* — дошман күрү, яратмау; күрә алмау, җене сөймәү.

**НЕНАВИ'СТНИК** *м.*, **НЕНАВИ'СТНИЦА** *ж. книж.* — дошман күрүче, күрә алмаучы.

**НЕНАВИ'СТНИЧЕСТВО** *ср. мн.* нет, *книж.* — дошманлык, күрә алмау(чылык), дошманлык мөнәсәбәте, күрә алмау мөнәсәбәте.

**НЕНАВИ'СТНЫЙ** — дошман..., нәфрәтле, явыз; *политика ненавистного царя* — явыз патша политикасы.

**НЕ'НАВИСТЬ** *ж. мн.* нет — нәфрәт, дошманлык, күрә алмау.

**НЕНАГЛЯ'ДНЫЙ** *разг.* — карап туймаслык, сөйкемле, сөекле, кадерле.

**НЕНАДЁЖНОСТЬ** *ж. мн.* нет — ышанычсыз булу, ышанычсызлык.

**НЕНАДЁЖНЫЙ** — ышанычсыз, ышанычы аз булган.

**НЕНА'ДОБНОСТЬ** *ж. мн.* нет — кирәксезлек, кирәксез булу, кирәге юклык. ◇ За ненадобностью — кирәксез булганга күрә, кирәкмәгәнгә күрә, кирәге булмаганга күрә.

**НЕНАДО'ЛГО** *нареч.* — кыска вакытка, аз гына вакытка, озакка...-мау; *ушёл ненадолго* — аз гына вакытка китте, озакка китмәде.

**НЕНАКАЗУ'ЕМЫЙ** *право* — җәза бирелми торган, җәза бирелергә тиеш булмаган.

**НЕНАПАДЕ'НИЕ** *только ед. ср. книж. полит.* — һөҗүм итмәү, сугыш ачмау.

**НЕНАРО'КОМ** *нареч. простореч.* — 1. ялгыш, ялгышлык белән (юри түгел, үч итеп түгел); 2. ничек тә бер, кайчан да бер; *ненароком к тебе зайду* — кайчан да бер сиңа кереп чыгармын.

**НЕНАРУШИ'МЫЙ** *книж.* — 1. *устар.* и *ритор.* үзгәртелмәслек, бозылмас, какшамас; *ненарушимые обеты* — бозылмас вәгъдәләр; 2. бозылмый торган, тулы; *ненарушимая тишина* — тулы тынлык.

**НЕНА'СТНЫЙ** — җил-давыллы, яңгырлы (көн, һава), буранлы (көн), бозык (һава), явымлы (көн).

**НЕНА'СТЬЕ** *ср. мн.* нет — бозык һава, һаваның бозыклыгы, явымлы-чәчемле, карлы-буранлы көннәр.

**НЕНАСЫ'ТНЫЙ** — 1. туймас тамак, мәңге туймас, ач күзле; комсыз; 2. *перен.* (*не удовлетворяющийся ничем достигнутым*) мәңге туймас, канәгатьләнмәс, канәгатьсез.

**НЕНАТУРА'ЛЬНЫЙ** — ясалма, табигый булмаган; *в знач. сказ.* ясалма, табигый түгел.

**НЕНАУ'ЧНЫЙ** — фәнни булмаган; *в знач. сказ.* фәнни түгел.

**НЕНОРМА'ЛЬНОСТЬ** *ж. книж.* — 1. нормаль булмау, нормаль булмаганлык, нормаль түгеллек; 2. нормаль булмаган хәл (күренеш).

**НЕНОРМА'ЛЬНЫЙ** — 1. нормаль булмаган; *в знач. сказ.* нормаль түгел; 2. *разг.* (*душевнобольной*) акылга зәгыйфь, акылдан язган.

**НЕНУ'ЖНЫЙ** — 1. кирәксез, кирәкмәгән; кирәксезгә..., бушка..., файдасызга...; *ненужная трата времени* — вакытны бушка үткәрү; 2. *в знач. сказ.* кирәк түгел, кирәге юк.

**НЕ'НЦЫ** — ненецлар, ненец халкы (Ненец, Ямало-Ненец милли округларында яшәүче халык).

**НЕОБДЕ'ЛАННЫЙ** *разг.* — 1. эшкәртеп җиткерелмәгән, эшкәртелеп бетмәгән; 2. (*без оправы*) кысага утыртылмаган.

**НЕОБДУ'МАННО** *нареч.* — уйламыйча, алдын-артын уйламастан (уйламыйча), дуамал, токтымал.

**НЕОБДУ'МАННЫЙ** — уйламый ...-ган, дуамал, токтымал ...-ган; *необдуманное письмо* — уйламый язылган хат.

**НЕОБЕСПЕ'ЧЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. тәэмин ителмәү, тәэмин ителмәгәнлек; 2. ярлылык.

**НЕОБЕСПЕ'ЧЕННЫЙ** — 1. тәэмин ителмәгән; 2. ярлы.

**НЕОБЖИТО'Й** *книж.*, **НЕОБЖИ'ТЫЙ** — кеше яшәмәгән, кеше яшәми торган.

**НЕОБИНУ'ЯСЬ** *нареч. устар.* — тартынмыйча, оялмыйча, кинаясез, уйлап-нитеп тормыйча, туп-туры, турыдан-туры, ачыктан-ачык; *сказать необинуясь что-нибудь* — кинаясез нәрсә дә булса әйтү.

**НЕОБИТА'ЕМОСТЬ** *ж. мн.* нет — кеше яшәмәү, кеше тормау.

**НЕОБИТА'ЕМЫЙ** — кеше яшәми торган, кеше тормый торган.

**НЕОБОЗРИ'МОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — киңлек, очсыз-кырыйсыз булу, иге-чиге булмау.

**НЕОБОЗРИ'МЫЙ** *книж.* — чиксез, очсыз-кырыйсыз, иге-чиге булмаган, иксез-чиксез, күз күреме җитмәс.

**НЕОБОСНО'ВАННОСТЬ** *ж. мн.* нет — нигезсезлек, нигезләвмәгән булу.

**НЕОБОСНО'ВАННЫЙ** — нигезсез, нигезләнмәгән.

**НЕОБРАБО'ТАННЫЙ** — 1. *с-х.* эшкәртелмәгән, эшләнмәгән; 2. начар эшкәртелгән; *необработанная статья* — начар эшкәртелгән мәкалә.

**НЕОБРАЗО'ВАННОСТЬ** *ж. мн.* нет — наданлык, надан булу, белемсезлек, укымаганлык, укымаган булу.

**НЕОБРАЗО'ВАННЫЙ** — белемсез, укымаган, надан.

**НЕОБРАТИ'МЫЙ** *науч.* — 1. кайтмас, кире юнәлештә кабатланмый торган; *необратимый процесс* — кире юнәлештә кабатланмый торган процесс; 2. урынын алмаштырып куйсаң әһәмиятен югалта торган.

**НЕОБРЕМЕНИ'ТЕЛЬНЫЙ** — җиңел, кыен булмаган.

**НЕОБУ'ЗДАННОСТЬ** *ж. мн.* нет — тыйнаксызлык, тотнаксызлык, йөгәнсезлек.

**НЕОБУ'ЗДАННЫЙ** — үз ирекле, тыйнаксыз, тотнаксыз; йөгәнсез, котырынкы.

**НЕОБХОДИ'МОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. кирәклек, кирәклелек, кирәкле булу; 2. *филос.* зарурлык; *о причинности и необходимости в природе* — табигатьтәге сәбәплелек һәм зарурлык турында.

**НЕОБХОДИ'МЫЙ** — 1. (*очень нужный*) кирәкле, бик кирәкле, үтә кирәкле, зарур булган; 2. (*обязательный, неизбежный*) кирәк булган, мәҗбүри, котылгысыз; 3. *филос.* зарур; 4. *безл. в знач. сказ.* кирәк, бик кирәк.

**НЕОБЩИ'ТЕЛЬНЫЙ** — аралашмый торган, аралашмаучан, аралашырга яратмаучан, кыргый.

**НЕОБЪЯСНИ'МЫЙ** — аңлатылмаслык, аңлатып бирерлек булмаган.

**НЕОБЪЯ'ТНЫЙ** *книж.* — чиксез зур, чиксез киң, күз күреме җитмәс.

**НЕОБЫКНОВЕ'ННЫЙ** — 1. (*чрезвычайный*) гадәттән тыш, чиктән тыш, искиткеч, бик зур; 2. (*странный, невероятный*) гаҗәп, кеше ышанмаслык, сәер.

**НЕОБЫЧА'ЙНОСТЬ** *ж.* — 1. *только ед.* үзенә бертөрле булу, үзенә бертөрлелек, башкаларга охшамаганлык; 2. (*необычайное явление*) гаҗәп хәл, искиткеч хәл, шаккатарлык хәл.

**НЕОБЫЧА'ЙНЫЙ** — үзенә бертөрле, гадәттән тыш, сирәк очрый торган, гаҗәп, искиткеч, шаккатарлык.

**НЕОБЫ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет — гадәттәгечә булмау.

**НЕОБЫ'ЧНЫЙ** — гадәттә булмаган; күнегелмәгән.

**НЕОБЯЗА'ТЕЛЬНЫЙ** — 1. (*не являющийся обязательным*) мәҗбүри булмаган; *в знач. сказ.* мәҗбүри түгел; 2. (*невнимательный, непредупредительный*) игътибарсыз, нәзакәтсез, лорфа, илтифатсыз.

**НЕОГЛЯ'ДНЫЙ** *книж.* — к. необозримый.

**НЕОГРАНИ'ЧЕННЫЙ** — чикләнмәгән.

**НЕОДИНА'КОВЫЙ** — төрле, бердәй булмаган, бертөрле булмаган; *в знач. сказ.* бердәй түгел, бертөрле түгел.

**НЕОДНОКРА'ТНО** *нареч.* — ничә тапкыр(лар), әллә ничә тапкыр, кабат-кабат, кат-кат.

**НЕОДНОКРА'ТНЫЙ** *книж.* — берничә тапкыр...-ган, кат-кат кабатланган; *неоднократные предупреждения* — берничә тапкыр ясалган кисәтүләр.

**НЕОДНОРО'ДНЫЙ** — 1. (*разнородный по составу*) төрле составлы, төрле-төрле составлы; 2. (*несходный*) бүтән, башка төрле, бер-берсенә охшамаган; *неоднородные явления* — бер-берсенә охшамаган күренешләр.

**НЕОДОБРЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — хупламау, яраклы дип тапмау, яраксыз дип табу, мактамау; яхшы дип тапмау.

**НЕОДОБРИ'ТЕЛЬНЫЙ** — начар, тискәре; *неодобрительный отзыв* — тискәре бәя.

**НЕОДОЛИ'МЫЙ** *поэт.* — к. непреодолимый.

**НЕОДУШЕВЛЁННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — җансызлык.

**НЕОДУШЕВЛЁННЫЙ** — җансыз.

**НЕОЖИ'ДАННО** *нареч.* — көтмәгәндә, көтелмәгәндә, кинәт, кинәттән, уйламастан, искәрмәстән, искәртмәстән, капыл.

**НЕОЖИ'ДАННОСТЬ** *ж.* — көтелмәгәнлек, көтелмәгән булу; көтелмәгән хәл, көтелмәгән вакыйга.

**НЕОЖИ'ДАННЫЙ** — көтелмәгән, көтмәгәндә...-ган, кинәт...-ган, искәрмәстән...-ган, искәртмәстән...-ган; *неожиданный гость* — көтмәгәндә килгән кунак.

**НЕОКРЕ'ПШИЙ** — ныгып җитмәгән, ныгымаган.

**НЕОЛИ'Т** *м. мн.* нет, *археол.* — неолит (таш гасырның соңгы дәвере).

**НЕОЛИТИ'ЧЕСКИЙ** *археол.* — неолит...-ы; неолитик; *неолитическая эпоха* — неолит дәвере, неолитик эпоха.

**НЕОЛОГИ'ЗМ** *м. лингв.* — неологизм (культура һәм техниканың үсеше, иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең үзгәреше яки үсеше нәтиҗәсендә барлыкка килгән яңа сүзләр, фразеологик берәмлекләр; шулай ук чит телләрдән кергән яңа терминнар да неологизм булып хисаплана).

**НЕО'Н** *м. мн.* нет, *хим.* — неон (химик элемент, затлы газ).

**НЕО'НОВЫЙ** *хим.* — неон тутырылган; *неоновая лампа* — неон тутырылган лампа.

**НЕОПА'СНЫЙ** — 1. куркынычсыз, куркыныч булмаган, зарарсыз; 2. *в знач. сказ.* куркынычсыз, зарарсыз, куркыныч түгел, зарарлы түгел.

**НЕОПЕРИ'ВШИЙСЯ** — 1. (*о птенце*) канат чыкмаган; 2. *перен. шутл.* канат чыкмаган, яшь, тәҗрибәсез.

**НЕОПИ'САННЫЙ** — 1. *(не подвергшийся описи)* исемлеккә кертелмәгән, язылмаган; 2. к. неописуемый 3.

**НЕОПИСУ'ЕМЫЙ** *книж.* — 1. тел белән әйтеп бирерлек булмаган, сүз белән әйтеп бирерлек булмаган; 2. *в знач. сказ.* тел (сүз) белән әйтеп бирерлек түгел, сөйләп бирерлек түгел; 3. искиткеч зур (көчле), бик зур (көчле); *неописуемая радость* — искиткеч зур шатлык.

**НЕОПЛА'ТНЫЙ: неоплатный долг** *разг.* — түләп бетергесез бурыч; **неоплатный должник** — бурычы күп кеше, бурычын түләп бетерә алмый торган кеше.

**НЕОПРА'ВДАННЫЙ** — 1. *(необоснованный)* нигезсез, нигезләнмәгән; 2. *(нецелесообразный)* тиешсез, тиеш булмаган.

**НЕОПРЕДЕЛЁННОСТЬ** *ж.* — билгесезлек, аныксызлык.

**НЕОПРЕДЕЛЁННЫЙ** — билгесез, аныксыз. ◇ **Неопределённое наклонение, неопределённая форма глагола** *грам.* — исем фигыль, инфинитив.

**НЕОПРЕДЕЛИ'МЫЙ** — билгеләве мөмкин булмаган, билгеләп булмый торган.

**НЕОПРОВЕРЖИ'МОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — кире кагылмаслык булу, инкарь ителмәслек булу.

**НЕОПРОВЕРЖИ'МЫЙ** *книж.* — кире кагылмаслык, инкарь ителмәслек, инкарь итәргә урын калмаган, бәхәсләшергә урын калмаган.

**НЕОПРЯ'ТНОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. шапшаклык, пычраклык; 2. керлелек.

**НЕОПРЯ'ТНЫЙ** — 1. шапшак, җыйнаксыз, үзен пычрак тотучан; 2. керле, каралган; *неопрятное платье* — керле күлмәк.

**НЕО'ПЫТНОСТЬ** *ж. мн.* нет — тәҗрибәсезлек.

**НЕО'ПЫТНЫЙ** — тәҗрибәсез, дөнья күрмәгән.

**НЕОРГАНИЗО'ВАННО** *нареч.* — таркау рәвештә, оешмаган рәвештә.

**НЕСЪЕДО'БНЫЙ** — ашарга ярамый торган, ашарга яраксыз.

**НЕСЫ'ТНЫЙ** — туклыксыз.

**НЕСЫ'ТЫЙ** — 1. ач; 2. *перен. книж.* комсыз; *несытые взгляды* — комсыз карашлар.

**НЕТ** — 1. юк; 2. *разг.* ...-ми(сен) икэн инде, югыйсә; *хочешь жить, как мы, милости просим, нет — так убирайся, проваливай* — безнеңчә торырга телисең икән, рәхим ит, теләмисең икән инде — үкчәңне күтәр; 3. булмас ла; *извольте узнать, сколько числом? — Душ восемьдесят.— Нет?— А ей-богу так* (Гоголь)—санын белергә мөмкинме?—Сиксән жан.—Булмас ла?—Валлаһи шулай; 4. *в знач. сказ.* түгел, ...-сыз; *он сильный, а ты нет* — ул көчле, ә син көчле түгел, ул көчле, ә син көчсез. ◇ **Нет и нет или нет да нет или нет как нет** *разг.*— юк та юк, һаман юк. **Нет, нет да и ...** *разг.* — юк-юк та, сирәк-мирәк кенә булса да; *нет-нет да и напишет письмо* — сирәк-мирәк кенә булса да хат яза. **А (то) нет?** *разг. фам.*— шулай түгелме әллә? шулай түгелмени? **Нет того, чтобы** *разг.*— ...-у урынына; *лежит! нет того, чтобы матери помочь!* — әнисенә ярдәм итү урынына тик ята. **На нет (свести или стесать, спилить, срубить** *и т. п.*) *разг.*— бөтенләйгә кисеп (юнып, чабып һ. б.) бетерү, кисә-кисә (юна-юна, чаба-чаба һ. б.) юкка чыгару. **Сводить на нет** *разг.* — юкка чыгару. **Сводиться на нет** *разг.* — юкка чыгу. **В нетях или в нетех** *книж. разг.*— юклар арасында (элек заманда гаскәри хезмәткә чакыру буенча килмәгәннәрнең исемлеген „нети"— „юклар" дип атый торган булганнар).

**НЕТАКТИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет — әдәпсезлек, тәрбиясезлек, гадәтсезлек.

**НЕТАКТИ'ЧНЫЙ** — әдәпсез, гадәтсез, тәрбиясез.

**НЕТАЛА'НТЛИВОСТЬ** *ж. мн.* нет — сәләтсезлек, талантсызлык.

**НЕТАЛА'НТЛИВЫЙ** — сәләтсез, талантсыз.

**НЕТА'ЛЫЙ** — эремәгән, эреми торган.

**НЕТВЁРДЫЙ** — 1. тотрыксыз, йомшак; *нетвёрдый характер* — йомшак характер; *нетвёрдая почва* — йомшак жир; 2. ныгымаган, какшау; 3. кыюсыз (йөрү).

**НЕ'ТЕЛЬ** *ж. обл.*— башмак тана.

**НЕТЕРПЁЖ** *м. простореч. фам. шутл.*— к. нетерпение.

**НЕТЕРПЕЛИ'ВЫЙ** — 1. сабырсыз, түземсез; *нетерпеливый человек* — түземсез кеше; 2. сабырсызлык белән...; *нетерпеливое ожидание* — сабырсызлык белән көтү.

**НЕТЕРПЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — сабырсызлык, түземсезлек.

**НЕТЕРПИ'МОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— 1. түзмәүчелек, кеше фикере белән санашмау; 2. түзә алмаслык дәрәҗәдә булу.

**НЕТЕРПИ'МЫЙ** *книж.*— 1. (*недопустимый*) түзә алмаслык, түзеп торгысыз, юл куярга ярамый торган; *в знач. сказ.* юл куеп булмый, килешеп булмый; *такие поступки нетерпимы* — мондый кыланышларга юл куеп булмый; 2. сүзен бирмәүчән, кеше фикере белән санашмаучан.

**НЕТЛЕ'ННЫЙ** — 1. *церк.* черемәс, черми торган; 2. *перен. книж. поэт. устар.* мәңгелек..., мәңге онытылмый торган, мәңге онытылмас; *нетленная слава* — мәңгелек дан.

**НЕТОПЫ'РЬ** *м.*— зур ярканат.

**НЕТОРОПЛИ'ВОСТЬ** *ж. мн.* нет — ашыкмаучылык, акрынлык, салмаклык.

**НЕТОРОПЛИ'ВЫЙ** — ашыкмый торган, акрын, салмак.

**НЕТО'ЧНОСТЬ** *ж.*— 1. хата, ялгышлык; дөрес булмау, анык булмау, дөрес түгеллек; 2. *мат.* төгәлсезлек.

**НЕТО'ЧНЫЙ** — 1. ялгыш, дөрес булмаган, аныксыз, анык булмаган; *в знач. сказ.* анык түгел, ялгыш, хата; 2. *мат.* төгәлсез.

**НЕТРЕ'БОВАТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет — талымсызлык, канәгать булу, таләпчән түгеллек, таләпчән булмау.

**НЕТРЕ'БОВАТЕЛЬНЫЙ** — талымсыз, канәгатьле, аз белән канәгатьләнүчән, таләпчән булмаган; *в знач. сказ.* таләпчән түгел.

**НЕТРЕ'ЗВОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. исереклек, аек булмау; 2. *перен.* ялгышлык.

**НЕТРЕ'ЗВЫЙ** — 1. исерек; 2. *перен.* ялгыш, аек булмаган (фикер, караш).

**НЕТРО'НУТЫЙ** — 1. тиелмәгән, кагылмаган, кул тимәгән, бөтен; 2. *перен.* бозылмаган, саф, чиста, гыйффәтле.

**НЕТРУДОВО'Й** — 1. хезмәт куймыйча табылган, эшләми табылган; *нетрудовой доход* — эшләми табылган керем; 2. (*эксплуататорский*) кеше хезмәтеннән файдаланучы, үз көче белән яшәми торган, эшләми ашаучы.

**НЕТРУДОСПОСО'БНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *офиц.* — хезмәткә яраксызлык, эшкә яраксызлык, хезмәткә яраксыз булу, эшкә яраксыз булу, хезмәткә (эшкә) ярамау.

**НЕТРУДОСПОСО'БНЫЙ** *офиц.* — хезмәткә яраксыз, эшкә яраксыз.

**НЕ'ТТО** *в знач. неизм. прил. торг.* — нетто, саф авырлык (товарның саф авырлыгы).

**НЕ'ТУ** *разг.* — юк.

**НЕ'ТЧИК** *м. устар.* — юклар арасындагы, качкын (элек заманда гаскәри хезмәткә чакыру буенча килмәгән кеше, гаскәри хезмәттән качып йөрүче).

**НЕУБЕДИ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет — ышандыра алмаслык булу, канәгатьләндерә алмаслык булу.

**НЕУБЕДИ'ТЕЛЬНЫЙ** — ышандыра алмаслык, ышандырып җиткерә алмаслык, канәгатьләндерә алмаслык.

**НЕУВАЖЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — ихтирам итмәү, санламау, санга сукмау, санга алмау.

**НЕУВАЖИ'ТЕЛЬНЫЙ** — 1. игътибарга алынмаслык; *неуважительная причина* — игътибарга алынмаслык сәбәп; 2. *просторечь. и устар.* к. непочтительный.

**НЕУВЕ'РЕННО** *нареч.* — икеләнеп, шикләнеп, ышанмыйча; кыюсыз; *неуверенно взглянуть* — кыюсыз карап кую.

**НЕУВЕ'РЕННОСТЬ** *ж.* — 1. кыюсызлык; 2. икеләнү, шикләнү, ышанып җитмәү.

**НЕУВЕ'РЕННЫЙ** — 1. (*колеблющийся*) шикләнүчән, икеләнүчән; 2. (*нерешительный*) кыюсыз, кыю булмаган.

**НЕУВЯДА'ЕМЫЙ** *книж. устар.* — к. неувядающий 2.

**НЕУВЯДА'ЮЩИЙ** — 1. шиңми торган, сулмый торган; 2. *перен. книж. ритор.* мәңгелек, гомерлек, мәңге бетмәс, мәңге онытылмас.

**НЕУВЯ'ЗКА** *ж.* к. несогласованность.

**НЕУГАСА'ЕМЫЙ** *книж.* — к. неугасимый.

**НЕУГАСИ'МЫЙ** *книж.* — 1. *церк.* сүнми торган, сүндерелми торган; 2. *перен.* сүнмәс, мәңге сүнмәс, сүнмәслек.

**НЕУГО'ДНЫЙ** *книж. устар.* — ярамаган, ошамаган, ошамый торган.

**НЕУГОМО'ННЫЙ** *разг.* — тынычсыз, тынгысыз, тик тормас; тынычлык бирми торган; *неугомонный ребёнок* — тынычсыз бала.

**НЕУДА'ЧА** *ж.* — уңышсызлык. ◇ Потерпеть неудачу — уңышсызлыкка очрау.

**НЕУДА'ЧЛИВЫЙ** — бервакытта да эше уңмый торган, бәхетсез.

**НЕУДА'ЧНИК** *м.*, **НЕУДА'ЧНИЦА** *ж.* — эше уңмый торган (кеше), бәхетсез (кеше).

**НЕУДА'ЧНЫЙ** — 1. уңышсыз; 2. начар; *неудачный лектор* — начар лектор.

**НЕУДЕРЖИ'МЫЙ** — тыелгысыз, тыеп булмый торган, бик көчле.

**НЕУДИВИ'ТЕЛЬНО** — гаҗәп түгел, искитәрлек түгел.

**НЕУДО'БНО** *нареч.* — уңайсыз, җайсыз.

**НЕУДО'БНЫЙ** — 1. уңайсыз, җайсыз; *неудобное место* — уңайсыз урын; 2. уңайсыз, кыен, читен; *поставить в неудобное положение* — уңайсыз хәлгә төшерү; 3. *разг.* урынсыз әйтелгән (сөйләнгән), әдәпсез; *неудобное выражение* — урынсыз әйтелгән сүз.

**НЕУДОБОВАРИ'МЫЙ** — 1. авыр, авыр сеңә торган; *неудобоваримая пища* — авыр аш; 2. *перен. ирон.* авыр аңлашыла торган.

**НЕУДОБОИСПОЛНИ'МЫЙ** *книж.* — башкаруы кыен булган, кыенлыклар белән генә башкарыла торган, кыен башкарыла торган.

**НЕУДОБОПОНЯ'ТНЫЙ** *книж.* — авыр аңлашыла торган, начар аңлашыла торган.

**НЕУДОБОПРОИЗНОСИ'МЫЙ** *книж.* — 1. *устар.* әйтүе читен булган, әйтүе кыен булган, авыр әйтелешле; 2. *шутл.* (*неприличный*) әйтүе уңайсыз булган, әдәпсез (сүз турында).

**НЕДУОБОЧИТА'ЕМЫЙ** *книж.* — укуы кыен булган, авыр аңлашыла торган.

**НЕУДО'БСТВО** *ср.* — 1. уңайсызлык, җайсызлык; *неудобство квартиры* — квартираның уңайсызлыгы; 2. *только ед.* (*состояние неприятности*) уңайсызлану.

**НЕУДО'БЬ** *нареч. старин.*: неудобь сказуемый *шутл.* — әйтүе уңайсыз булган, әйтүе оят булган.

**НЕУДОВЛЕТВОРЁННОСТЬ** *ж. мн.* нет — канәгатьләнмәү, канәгатьләндерелмәү; канәгатьсезлек, ризасызлык.

**НЕУДОВЛЕТВОРЁННЫЙ** — канәгатьләндерелмәгән.

**НЕУДОВЛЕТВОРИ'ТЕЛЬНО** *нареч.* — канәгатьләндерерлек дәрәҗәдә ...-мау, канәгатьләнерлек итеп ...-мау, начар; *работа сделана неудовлетворительно* — эш канәгатьләндерерлек дәрәҗәдә үтәлмәгән, эш начар башкарылган.

**НЕУДОВЛЕТВОРИ'ТЕЛЬНЫЙ** — канәгатьләнерлек булмаган, канәгатьләндерерлек итеп ...-маган, канәгатьләндерерлек дә-

рәҗәдә ...-маган, начар; *неудовлетворительная работа* — канәгатьләндерерлек итеп эшләнмәгән эш; *в знач. сказ.* канәгатьләнерлек түгел.

**НЕУДОВО'ЛЬСТВИЕ** *ср. книж.* — ризасызлык, риза түгеллек, риза булмау, канәгать булмау.

**НЕУЁ'МНЫЙ** *книж.* — туктамый торган, туктамас, бетми торган, бетмәс, тынгысыз, тынычландырып (туктатып) булмый торган.

**НЕУЖЕ'ЛИ** *вопросит. нареч.* — чынлап та ...-мы? *неужели он согласился?* — чынлап та ул риза булганмы? ◇ **Неужели?!** — китсәнә?! булмас ла!?

**НЕУЖИ'ВЧИВОСТЬ** *ж. мн. нет* — тыныша алмау, сыеша алмау.

**НЕУЖИ'ВЧИВЫЙ** — кеше белән тыныша алмый торган, кеше белән тыныша алмаучан; кеше белән тату тора алмый торган, тар холыклы; мыгырдык, вак сүзле, әрепләшүчән, тиргәшүчән; *неуживчивый человек* — кеше белән тыныша алмаучан кеше.

**НЕУ'ЖЛИ'** *нареч. обл. устар.* — к. неужели.

**НЕ'УЖТО** *нареч. разг.* — к. неужели.

**НЕУЗНАВА'ЕМОСТЬ** *ж. книж.*: **до неузнаваемости** — танымаслык хәлгә (килү, китерү); **похудел до неузнаваемости** — танымаслык булып ябыккан.

**НЕУЗНАВА'ЕМЫЙ** *книж.* — танымаслык, таный алмаслык.

**НЕ'УК** *м.* — 1. *устар.* надан, дорфа, тупас; 2. *обл. с.-х.* өйрәтелмәгән ат.

**НЕУКА'ЗАННЫЙ** *офиц. устар.* — тыелган, рөхсәт ителмәгән.

**НЕУКЛО'ННО** *нареч.* — тайпылусыз, тайпылышсыз, тайпылмастан.

**НЕУКЛО'ННЫЙ** *книж.* — 1. (*непоколебимый*) тайпылусыз, тайпылышсыз; какшамас; 2. өзлексез; *неуклонный рост производительных сил* — житештерү көчләренең өзлексез үсүе.

**НЕУКЛЮ'ЖЕСТЬ** *ж. мн. нет* — 1. авыр сөяклелек; 2. шыксызлык, килбәтсезлек.

**НЕУКЛЮ'ЖИЙ** *разг.* — 1. авыр сөякле; *неуклюжий человек* — авыр сөякле кеше; 2. шыксыз, ямьсез; *неуклюжий вид* — шыксыз кыяфәт.

**НЕУКОСНИ'ТЕЛЬНЫЙ** *устар.* — тайпылышсыз, тайпылусыз; мәжбүри.

**НЕУКРОТИ'МОСТЬ** *ж. мн. нет, книж.* — тыйнаксызлык, тыелгысызлык, котырынкылык.

**НЕУКРОТИ'МЫЙ** *книж.* — 1. кулга ияләнми (өйрәнми) торган, кулга ияләндереп (өйрәтеп) булмый торган; *неукротимый зверь* — кулга ияләнми (ияләндереп булмый) торган ерткыч; 2. тыелгысыз, дуамал, котырынкы, ярсулы; *неукротимый характер* — дуамал характер; *неукротимый гнев* — ярсулы ачу.

**НЕУЛОВИ'МОСТЬ** *ж. мн. нет, книж.* — тотылмау(чанлык); 2. сизелер-сизелмәс(лек) булу.

**НЕУЛОВИ'МЫЙ** — 1. тотылмый торган, тотып булмый торган; *неуловимый вор* — тотылмый торган карак; 2. сизелер-сизелмәс, күренер-күренмәс; *неуловимое движение* — сизелер-сизелмәс хәрәкәт.

**НЕУМЕ'ЛЫЙ** — 1. белдексез, кулыннан килми торган, уңмаган, осталыгы булмаган; *неумелая швея* — белдексез тегүче; 2. белер-белмәс эшләнгән (башкарылган), белмичә эшләнгән (башкарылган), начар эшләнгән; *неумелая работа* — белер-белмәс (начар) башкарылган эш.

**НЕУМЕ'НИЕ** *ср. мн. нет* — белмәү, булдыра алмау.

**НЕУМЕ'РЕННОСТЬ** *ж. мн. нет* — 1. чамадан тыш булу; 2. тотнаксызлык, чама белмәү, канәгатьләнә белмәү.

**НЕУМЕ'РЕННЫЙ** — 1. чамадан тыш; 2. (*о человеке*) тотнаксыз, чама белмәүчән, чама белмәүче, канәгатьләнә белмәүчән.

**НЕУМЕ'СТНОСТЬ** *ж. мн. нет* — урынсызлык.

**НЕУМЕ'СТНЫЙ** — урынсыз.

**НЕУ'МНЫЙ** — 1. (*о человеке*) акылсыз, акылга сай, ахмак; 2. (*о поступках*) акылсыз, акыл белән эшләнмәгән.

**НЕУМОЛИ'МОСТЬ** *ж. мн. нет, книж.* — 1. сүзгә күнмәүчәнлек; 2. *перен.* котылгысызлык.

**НЕУМОЛИ'МЫЙ** *книж.* — 1. сүзгә күнмәүчән, сүзгә күндереп булмый торган; *неумолимый человек* — мәрхәмәтсез кеше; 2. *перен.* бозылмый торган, бозылмас, үзгәрми торган, үзгәрмәс, котылгысыз; *неумолимые законы природы* — табигатьнең котылгысыз законнары.

**НЕУМОЛКА'ЕМЫЙ** *книж.* — к. несмолкаемый.

**НЕУМО'ЛЧНЫЙ** *поэт.* — к. несмолкаемый.

**НЕУМЫ'ТНЫЙ** *книж. устар.* — к. бескорыстный.

**НЕУМЫ'ШЛЕННЫЙ** — ялгышлык белән эшләнгән, ихтыярсыз эшләнгән, усал уй белән эшләнмәгән, явыз ният белән эшләнмәгән, алдан уйлап эшләнмәгән; *неумышленное преступление* — ихтыярсыз эшләнгән җинаять, алдан уйлап эшләнмәгән җинаять.

**НЕУПЛА'ТА** *ж. мн. нет, канц.* — түләмәү.

**НЕУПОТРЕБИ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн. нет* — кулланылмау.

**НЕУПОТРЕБИ'ТЕЛЬНЫЙ** — кулланылмый торган.

**НЕУРАВНОВЕ'ШЕННОСТЬ** *ж. мн. нет* — тотнаксызлык, тотрыксызлык, холыксызлык.

**НЕУРАВНОВЕ'ШЕННЫЙ** — тотрыксыз табигатьле, холыксыз.

**НЕУРОЖА'Й** *м.* — уңыш булмау (ашлык, җимеш һ. б. турында).

**НЕУРОЖА'ЙНЫЙ** — уңыш начар булган, игеи уңмаган; *неурожайный год* — иген уңмаган ел.

**НЕУРО'ЧНЫЙ: придти в неурочное время (час)** — вакытсыз килү; **работать в**

**неурочное время** — билгеләнгән вакыттан тыш эшләү.

**НЕУРЯ'ДИЦА** *ж. разг.* — 1. (*беспорядок)* тәртипсезлек; 2. *чаще мн.* (*недружные отношения*) орыш-талаш, әрләшү, ыгы-зыгы.

**НЕУСИ'ДЧИВОСТЬ** *ж. мн.* нет — бирелеп эшли алмау, чуар йөрәклелек.

**НЕУСИ'ДЧИВЫЙ** — бирелеп эшли алмаучан, чуар йөрәкле.

**НЕУСПЕ'Х** *м.* — уңышсызлык.

**НЕУСПЕ'ШНЫЙ** — уңышсыз.

**НЕУСТА'ННО** *нареч.* — бертуктаусыз, армый-талмый.

**НЕУСТА'ННЫЙ** *книж.* — бертуктаусыз, өзлексез, армый-талмый...; *неустанная работа* — армый-талмый эшләү.

**НЕУСТО'ЙКА** *ж. право* — неустойка (килешү шартларын үтәмәгән өчен түләнә торган штраф).

**НЕУСТО'ЙЧИВОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. какшап тору, селкенүчән булу; 2. аумакайлык, сүздә (фикердә) нык тормау; 3. үзгәрүчәнлек.

**НЕУСТО'ЙЧИВЫЙ** — 1. какшау, селкенә торган, ауныклый торган; *неустойчивый стул* — какшау урындык, селкенә торган урындык; 2. *перен.* (*колеблющийся*) сүзендә (фикерендә) нык тормаучан, аумакай; 3. (*изменчивый*) үзгәрүчән, үзгәреп тора торган.

**НЕУСТРАНИ'МЫЙ** *книж.* — котылгысыз, котылып булмый торган, бетереп булмый торган.

**НЕУСТРАШИ'МОСТЬ** *ж. мн.* нет — куркусызлык, куркусыз булу, кыюлык, батыр йөрәклелек.

**НЕУСТРАШИ'МЫЙ** — куркусыз, кыю, батыр йөрәкле.

**НЕУСТРО'ЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. тәртипкә салынмау, җайга салынмау, рәткә салынмау; 2. тормышы тәртипкә (рәткә) салынмау.

**НЕУСТРО'ЕННЫЙ** — 1. тәртипкә салынмаган, рәткә салынмаган, җайга салынмаган; 2. тормышы тәртипкә (рәткә) салынмаган; *неустроенный человек* — тормышы тәртипкә салынмаган кеше.

**НЕУСТРО'ЙСТВО** *ср. книж.* — тәртипкә (рәткә) салынмау, тәртипкә (рәткә) салынмаган булу.

**НЕУСТУ'ПЧИВОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — юл куймау, сүзгә күнмәү, сүзен бирмәү.

**НЕУСТУ'ПЧИВЫЙ** — үз сүзле, юл куймаучан, сүзгә күнмәүчән, сүзен бирмәүчән.

**НЕУСЫ'ПНЫЙ** *книж.* — бертуктаусыз; *неусыпный надзор* — бертуктаусыз күзәтү.

**НЕУТЕШИ'ТЕЛЬНЫЙ** — күңелсез, күңелне тынычландырмый торган.

**НЕУТЕ'ШНЫЙ** — юанычсыз, күңелсез.

**НЕУТОЛИ'МЫЙ** — басылмаслык, басылмас, басып булмый торган, бик көчле, бик нык.

**НЕУТОМИ'МО** *нареч.* — армый-талмый, аруны-талуны белмичә.

**НЕУТОМИ'МЫЙ** — 1. арусыз, армый-талмый эшли торган, аруны-талуны белми торган, аруны-талуны белмәүчән; *неутомимый работник* — аруны-талуны белми торган эшче; 2. армый-талмый, бертуктаусыз, иксез-чиксез; *неутомимые разговоры* — бертуктаусыз сөйләшүләр.

**НЕ'УЧ** *м. разг. пренебр.* — надан.

**НЕУЧЁНЫЙ** *простореч.* — укымаган, надан.

**НЕУЧТИ'ВОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — ихтирамсызлык, әдәпсезлек, тәрбиясезлек.

**НЕУЧТИ'ВЫЙ** *книж.* — ихтирамсыз, әдәпсез, тәрбиясез.

**НЕУЮ'ТНЫЙ** — уңайсыз, җайсыз, ипсез, җыйнаксыз.

**НЕУЯЗВИ'МОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — 1. ныклык, түземлелек; *неуязвимость характера* — характерның түземлелеге; 2. ышанычлылык, яхшы нигезләнгән булу, бәйләнә алмаслык булу.

**НЕУЯЗВИ'МЫЙ** *книж.* — 1. түзем, түземле, сүз күтәрүчән; *неуязвимое сердце* — түземле йөрәк; *неуязвимый человек* — сүз күтәрүчән кеше; 2. нык, ышанычлы, яхшы нигезләнгән, тел тидергесез; инкарь итә алмаслык, бәйләнә алмаслык; *неуязвимое доказательство* — яхшы нигезләнгән дәлил.

**НЕФТЕНАЛИВНО'Й** *спец.* — нефть ...-ы; нефть ташый торган; *нефтеналивная баржа* — нефть баржасы, нефть ташый торган баржа.

**НЕФТЕНО'СНЫЙ** — нефть табыла торган, нефть чыга торган; *нефтеносные слои* — нефть табыла торган катламнар.

**НЕФТЕПЕРЕГО'ННЫЙ** — нефть куа торган (нефтьне керосин, бензин һ. б. продуктларга аера торган).

**НЕФТЕПЕРЕРАБА'ТЫВАЮЩИЙ** — нефть эшкәртә торган.

**НЕФТЕПРОВО'Д** *м. тех.* — нефтепровод (нефтьне яки нефть продуктларын агызу трубасы).

**НЕФТЕПРОДУ'КТ** *м. хим. тех.* — нефть продукты (мәсәлән, керосин, бензин, мазут, вазелин һ. б.).

**НЕФТЕПРОМЫ'ШЛЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет — нефть промышленносте.

**НЕФТЕПРОМЫ'ШЛЕННЫЙ** — нефть промышленносте ...-ы; *нефтепромышленное предприятие* — нефть промышленносте предприятиесе.

**НЕФТЕХРАНИ'ЛИЩЕ** *ср. тех.* — нефть саклау урыны, нефтехранилище (нефть саклау өчен хезмәт итә торган корылма).

**НЕФТЬ** *ж. мн.* нет, *спец.* — нефть.

**НЕФТЯ'НИК** *м.* — нефтьче (нефть промышленносте эшчесе, техникы, инженеры).

**НЕФТЯ'НКА** *ж. тех.* — нефтянка (нефть белән эшли торган двигатель яки паровоз).

**НЕФТЯНО'Й** — 1. нефть ...-ы; *нефтяной фонтан* — нефть фонтаны; *нефтяной промысел* — нефть промыселы; *нефтяной двигатель* — нефть двигателе; 2. нефтьтән чыгарыла (аерыла) торган; нефть ...-ы; *нефтяной газ* — нефть газы; *нефтяной эфир* —

нефтьтән чыгарыла (аерыла) торган эфир; 3. к. нефтеносный.

**НЕХВАТА'ТЬ** *несов. безл.* — җитмәү; *не-хватает времени* — вакыт җитми.

**НЕХВАТИ'ТЬ** *сов.* — к. нехватать.

**НЕХВА'ТКА** *ж. разг.* — җитешмәүчелек, җитешмәү, җитмәү.

**НЕХИ'ТРЫЙ** — 1. хәйләсез, эчкерсез, беркатлы; 2. *разг.* җиңел, катлаусыз; *не-хитрое дело* — җиңел эш.

**НЕХОРО'ШИЙ** — начар.

**НЕ'ХОТЯ** *нареч. разг.* — теләр-теләмәс, теләмичә, көчәнеп.

**НЕЦЕЛЕСООБРА'ЗНОСТЬ** *ж. мн.* нет — файдасызлык, файдасыз булу, максатка туры килмәү, максатка ярашлы булмау.

**НЕЦЕЛЕСООБРА'ЗНЫЙ** — файдасыз, максатка туры килми торган, максатка ярашлы булмаган. ◇ **Нецелесообразная трата времени** — вакытны бушка сарыф итү. **Нецелесообразное решение** — мәгъ-нәсез карар.

**НЕЦЕНЗУ'РНЫЙ** — 1. цензура аша үт-мәслек; *нецензурные стихи Пушкина* — Пушкинның патша цензурасы аша үтмәс-лек шигырьләре; 2. *перен.* әдәпсез, әшәке; *нецензурные слова* — әдәпсез сүзләр.

**НЕЦЕРЕМО'ННЫЙ** — тәкәллефсез, тар-тынусыз.

**НЕЧА'ЕМЫЙ** *книж. устар.* — көтелмә-гән, көтмәгән.

**НЕЧА'ЯННО** *нареч.* — 1. ялгыш, сизмәс-тән; *нечаянно выстрелить* — ялгыш атып җибәрү; 2. *(неожиданно)* көтмәгәндә, ки-нәт, очраклы рәвештә.

**НЕЧА'ЯННОСТЬ** *ж. книж.* — 1. ялгыш-лык; 2. көтелмәгәнлек, кинәтлек; 3. *разг.* көтелмәгән хәл (вакыйга). ◇ **По нечаян-ности** *разг.* — ялгыш, ялгышлык белән.

**НЕЧА'ЯННЫЙ** — 1. *(неосторожный)* ял-гыш..., ялгышлык белән...; 2. *(неожидан-ный)* көтелмәгән, көтмәгән; кинәт булган.

**НЕ'ЧЕГО** I *местоим. с инф.* — юк; *нече-го рассказывать* — сөйлисе сүз юк. ◇ **Не-чего делать** — 1. эш юк; 2. һичнәрсә эш-ләп булмый, нишләп тә булмый инде. **От нечего делать** — эш юктан, эш юктан эш итеп. **Нечего сказать** — 1. әйтер сүз юк; 2. әйтәсе дә юк инде, сөйләп тә торасы юк инде, харап инде, әйтерлек тә түгел.

**НЕ'ЧЕГО** II *в знач. сказ. с инф. несов. вида разг.* — 1. ...-сы юк, ярамый; *об этом и думать нечего* — бу турыда уйлап та торасы юк; *нечего нам здесь оставать-ся* — безгә монда калырга ярамый; 2. ...-ып торма, ...-ып та торасы юк, ... кирәге юк; *нечего вам в это дело мешаться* — сез-нең бу эшкә тыгылуыгызның кирәге юк. ◇ **От нечего делать** — эш юктан эш итеп.

**НЕЧЕЛОВЕ'ЧЕСКИЙ** *книж.* — кеше кө-ченнән (хәленнән, кулыннан) килмәслек, кеше булдыра алмаслык; чиктән тыш зур.

**НЕЧЕЛОВЕ'ЧНЫЙ** — кешелексез, мәр-хәмәтсез, шәфкатьсез.

**НЕЧЕСТИ'ВЕЦ** *м.*, **НЕЧЕСТИ'ВИЦА** *ж. книж. устар.* — мөртәт, мөнафикъ.

**НЕЧЕСТИ'ВЫЙ** *книж. устар.* — гө-наһлы, бозык, мөнафикъ...; *нечестивый че-ловек* — гөнаһлы (бозык) кеше.

**НЕЧЕ'СТИЕ** *ср. книж. устар.* — гөнаһ-лылык, бозыклык, мөнафикълык.

**НЕЧЕ'СТНЫЙ** — намуссыз, вөҗдансыз, турылыксыз.

**НЕ'ЧЕТ** *м. разг.* — так; *чёт и нечет* — такмы — җөпме (уен).

**НЕЧЁТКИЙ** — 1. тонык; *нечёткий рису-нок* — тонык рәсем; 2. танылмаслык; *нечёт-кий почерк* — танылмаслык почерк; 3. ачык ...-мау; *нечёткое произношение* — ачык әйтмәү.

**НЕЧЁТНЫЙ** — так, икегә бүленми торган.

**НЕЧИСТОПЛО'ТНОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. шапшаклык, шакшылык, пычраклык; 2. *перен.* вөҗдансызлык, оятсызлык.

**НЕЧИСТОПЛО'ТНЫЙ** — 1. шапшак, шак-шы, үзен пычрак тотучан; 2. *перен.* вөҗ-дансыз, оятсыз.

**НЕЧИСТОТА'** *ж.* — 1. пычраклык, шак-шылык; 2. *только мн.* шакшылар.

**НЕЧИ'СТЫЙ** — 1. керле; *нечистое бельё* — керле бельё; 2. пычрак, шакшы; *нечистая посуда* — пычрак савыт-саба; 3. *религ.* харам; *нечистая пища* — харам аш; 4. алдаулы, алдауга корылган; *нечи-стая игра* — алдауга корылган уен; 5. җит-кереп эшләнмәгән, начар. ◇ **Нечистая сила** — җен, шайтан, пәри. **На руки не-чист** — кәкре куллы, кулы кәкре, кулы тик тормый (карак мәгънәсендә). **Нечистая по-рода** — нәселсез токым.

**НЕ'ЧИСТЬ** *ж. мн.* нет, *собир. просто-реч.* — 1. җеннәр, шайтаннар, пәриләр; 2. *бран. презрит.* түбән кешеләр; 3. *пе-рен. пренебр. (отбросы)* шакшылар.

**НЕЧЛЕНОРАЗДЕ'ЛЬНЫЙ** — аңлаешсыз.

**НЕ'ЧТО** *местоим. книж.* — нәрсәдер, нидер, бернәрсә, бер әйбер.

**НЕЧУВСТВИ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — сизмәү, сизмәүчәнлек.

**НЕЧУВСТВИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.* — 1. сиз-ми торган, тоймый торган; *нечувствитель-ный к холоду* — суыкны сизми торган; 2. сизмәүчән, сизгерлеген югалткан; *не-чувствительный к красоте* — матурлыкны сизмәүчән. ◇ **Нечувствительным обра-зом** — сизмәстән, сиздермичә.

**НЕШИРО'КИЙ** — тар, шактый тар.

**НЕ'ШТО** *нареч. простореч.* — 1. әллә инде ...-мы? *да нешто впервой мне это самое?* — әллә инде бу минем өчен берен-че тапкырмы?

**НЕШУ'ТОЧНЫЙ** *разг.* — шактый әһә-миятле, җитди; *нешуточная болезнь* — җитди авыру; *нешуточные слова* — шак-тый әһәмиятле сүзләр. ◇ **Нешуточное дело** — уен эш түгел.

**НЕЩА'ДНО** *нареч.* — аяусыз рәвештә, рәхимсез рәвештә.

**НЕЩА'ДНЫЙ** — аяусыз, рәхимсез, мәр-хәмәтсез, шәфкатьсез.

**НЕЯ'ВКА** *ж. мн.* нет, *офиц.* — килмәү.

**НЕЯ'СНОСТЬ** *ж.* — аңлаешсызлык, аңла-ешлы булмау, анықсызлык, анык булмау.

**НЕЯ'СНЫЙ** — 1. тонык, сизелмәслек, сизелер-сизелмәс; *неясные линии* — тонык сызыклар; 2. аңлаешсыз, аңлашылмый торган, аныксыз, ачык булмаган; *неясная мысль* — ачык булмаган фикер; *имеется неясное место в книге* — китапта аңлаешсыз бер урын бар; *в знач. сказ.* аңлашылмый, ачык түгел.

**НЕЯ'СЫТЬ** *ж. зоол.* — соры ябалак.

**НИ** *частица* — 1. *(перед сущ. в сочетании со словом „один" или без него)* бер... дә, бер генә... дә; *в ведре ни (одной) капли воды нет* — чиләктә бер генә тамчы да су юк; 2. *(после местоимений перед глаголом)* ... гына ...-ма; ... гына ...- са да; *кто бы (то) ни был* — кем генә булмасын, кем генә булса да; *сколько ни просили, не соглашается* — күпме генә үтенсәләр дә, риза булмый; 3. ... да булмый, ... да булмый; ... да, ... да булмый; *ни встать ни сесть* — торып та булмый, утырып та булмый; торып та, утырып та булмый; 4. ... да түгел,... да түгел; *ни рыба ни мясо* — балык та түгел, ит тә түгел; 5. ... да юк, ... да юк; *ни слова, ни привета* — сүз дә юк, сәлам дә юк. ◇ **Ни два ни полтора** — ни ары, ни бире. **Какой ни на есть** — нинди генә булса да; нинди дә бер, нинди дә булса. **Кто ни на есть** — кем генә булса да. **Где ни на есть** — кайда гына булса да. **Что ни на есть** *простореч.* — ...-ның да; *товар что ни на есть лучший* — товарның да иң яхшысы. **Ни с места!** — урыныңнан да кузгалма! **Ни гу-гу** — авызыңны да ачма! телеңне дә кыймылдатма! **Ни слова!** — авызыңны да ачма! Май кап! **Ни шагу!** — бер адым да атлама! **Ни в зуб (толкнуть)** *школьн. арго* — һичбер нәрсә белми; бернәрсә дә белми; *его спрашивают, а он ни в зуб толкнуть* — аннан сорыйлар, ә ул бернәрсә дә белми. **Ни с того, ни с сего** — тик торганда, һичбер сәбәпсез.

**-НИБУДЬ и НИБУ'ДЬ** *частица* — да булса; *кто-нибудь* — кем дә булса; *как-нибудь* — ничек тә булса.

**НИ'ВА** *ж.* — 1. *поэт. обл.* кыр, басу; 2. *перен. книж. ритор. устар.* өлкә, юл; *трудился на ниве народного просвещения* — халыкны агарту өлкәсендә (юлында) эшләде.

**НИВЕЛИ'Р** *м. геодез.* — нивелир (оптик прибор).

**НИВЕЛИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.* — 1. *геодез.* нивелирлау (җир өстендәге нокталарның бер-берсеннән никадәр биегрәк яки түбәнрәк булуын үлчәп белү); 2. *перен. книж.* тигезләү, бетерү (ике арадагы аерманы бетерү).

**НИВЕЛИ'РОВАТЬСЯ** — 1. *несов. страд.* нивелирлану; 2. *сов.* и *несов. книж.* тигезләнү, бетү.

**НИВЕЛИРО'ВЩИК** *м. спец.* — нивелирлаучы.

**НИВЕ'СТЬ** *нареч. простореч.* — к. невесть.

**НИ'ВХИ** *нескл.* — нивхлар, нивх халкы (Сахалинда һәм Амур елгасы тамагында яшәүче халык; электә аларны гиляклар дип атаганнар).

**НИГДЕ'** *нареч.* — һичбер җирдә, һичкайдә, беркайда да.

**НИГИЛИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *книж.* — нигилизм (1. *истор.* нигилистлар карашы; 2. барлык традицияләрне, принципларны инкарь итү).

**НИГИЛИ'СТ** *м. книж. устар.* — нигилист (1. XIX гасырның 60 нчы елларында дворян-буржуаз җәмгыятьнең идеологиясенә һәм традицияләренә каршы чыгучы прогрессив фикерле кешеләргә бирелгән исем; 2. барлык традицияләрне, принципларны инкарь итүче).

**НИГИЛИСТИ'ЧЕСКИЙ** *книж.* — нигилистик, нигилистларча...; *нигилистический взгляд* — нигилистларча караш.

**НИГИЛИ'СТСКИЙ** *книж.* — к. нигилистический.

**НИЖА'ЙШЕ** *нареч.* — түбәнчелек белән, түбәнчелек күрсәтеп, ихтирам итеп; *нижайше кланяться* — түбәнчелек белән (түбәнчелек күрсәтеп) баш ию.

**НИ'ЖЕ** — түбәнрәк, астарак; тәбәнәгрәк. ◇ **Ниже достоинства** *книж.* — ... өчен түбәнлек; *это ниже моего достоинства* — бу минем өчен түбәнлек. **Ниже всякой критики** — тәнкыйтьтән түбән, телгә алмаслык, телгә дә алырлык түгел. **Заговорил тоном ниже** — тавышын басыбрак сөйли башлады.

**НИЖЕ'** *союз присоедин., церк. книж. устар. (употребл. после отрицательных предложений)* — хәтта.

**НИЖЕИЗЛО'ЖЕННЫЙ** *книж.* — түбәндә әйтелгән (язылган һ. б.).

**НИЖЕОЗНА'ЧЕННЫЙ** *книж. устар.* — түбәндә күрсәтелгән.

**НИЖЕПОДПИСА'ВШИЙСЯ** *офиц. канц.* — түбәндә кул куйган, түбәндә кул куючы.

**НИЖЕПОИМЕНО'ВАННЫЙ** *офиц. канц.* — түбәндә аталган, түбәндә күрсәтелгән.

**НИЖЕСКА'ЗАННЫЙ** *книж. устар.* — к. нижеизложенный.

**НИЖЕСЛЕ'ДУЮЩИЙ** *книж.* — түбәндәге.

**НИЖЕУПОМЯ'НУТЫЙ** — түбәндә күрсәтелгән (әйтелгән һ. б.).

**НИ'ЖНИЙ** — 1. түбәнге, аскы; *нижний этаж* — аскы кат; 2. эчке; *нижняя рубашка* — эчке күлмәк; 3. түбән агым; *нижняя Волга* — Волганың түбән агымы. ◇ **Нижний чин** *дореволюц. воен.* — түбән чин (солдат).

**НИЗ** *м. мн.* нет — 1. түбәнге кат, аскы кат; *низ дома* — өйнең түбәнге каты; 2. ас, ас як; *низ фарфоровых изделий не глазируется* — фарфордан ясалган әйберләрнең асты (аскы ягы) глазурь белән капланмый (ялтыратылмый); 3. түбән; *ехать на низ* — түбәнгә таба бару; 4. *только мн. дорев.* түбәнге катлау; *голод вызвал волнения в низах* — ачлык түбәнге катлаулар арасында чуалышлар тудырды; 5. *чаще мн.*

халык, киң массалар; *не отрываться от низов* — киң массалардан аерылмаска.

**НИЗА'ТЬ** *несов.* — җепкә тезү. ◇ **Так и нижет глазами** — үтә күрә (эчендәге барлык серләрне белә).

**НИЗА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — җепкә тезелү.

**НИЗАЧТО'** *нареч.* — әллә нигә дә, ни эшләтсәләр дә; *низачто не поеду* — әллә нигә дә бармыйм.

**НИЗВЕРГА'ТЬ** *несов. книж. ритор. устар.* — к. низвергнуть.

**НИЗВЕРГА'ТЬСЯ** *несов. книж. ритор. устар.* — 1. өстән төшү, югарыдан төшү; 2. *страд.* бәреп төшерелү.

**НИЗВЕ'РГНУТЬ** *сов. книж. ритор. устар.* — бәреп төшерү.

**НИЗВЕ'РГНУТЬСЯ** *сов. книж. ритор. устар.* — югарыдан егылып төшү.

**НИЗВЕСТИ'** *сов. книж. устар.* — төшерү.

**НИЗВОДИ'ТЬ** *книж. устар.* — к. низвести.

**НИЗВОДИ'ТЬСЯ** *несов. страд. книж. устар.* — төшерелү.

**НИЗИ'НА** *ж. мн.* нет, *разг.* — уйсу урын, уйсулык.

**НИ'ЗИТЬСЯ** *несов. устар.* — түбәнәю, түбәнәя төшү.

**НИ'ЗКА** *ж. спец.* — 1. тезү; 2. берәр нәрсә тезелгән җеп.

**НИ'ЗКИЙ** — 1. тәбәнәк, карсак; *низкий рост* — тәбәнәк буй; 2. *перен. презр.* түбән; кабахәт; *низкий человек* — түбән кеше; 3. түбән; *низкие цены* — түбән бәяләр; 4. калын; *низкий голос* — калын тавыш. ◇ **Низкий лоб** — тар маңгай.

**НИЗКОЛО'БЫЙ** — тар маңгайлы.

**НИЗКОПОКЛО'ННИК** *м. книж. презрит.* — ялагай, юмакай, тәлинкә ялаучы.

**НИЗКОПОКЛО'ННИЧАТЬ** *несов. книж. презрит.* — ялагайлану, юмакайлану, тәлинкә ялау.

**НИЗКОПОКЛО'ННИЧЕСТВО, НИЗКОПОКЛО'НСТВО** *ср. мн.* нет — ялагайлык юмакайлык, тәлинкә ялау.

**НИЗКОПРО'БНЫЙ** — түбән сыйфатлы, начар.

**НИЗКОРО'СЛЫЙ** — тәбәнәк (буйлы), карсак.

**НИЗКОСО'РТНЫЙ** — түбән сыйфатлы, начар сортлы, түбән сортлы.

**НИЗКОСТВО'ЛЬНЫЙ** *спец.* — 1. *(об отдельных растениях)* тәбәнәк кәүсәле; 2. *(о лесе)* вак.

**НИЗЛАГА'ТЬ** *несов. книж.* — к. низложить.

**НИЗЛАГА'ТЬСЯ** *несов. страд. книж.* — төшерелү (урыннан, тәхеттән).

**НИЗЛОЖИ'ТЬ** *сов. книж.* — төшерү (урыннан, тәхеттән).

**НИ'ЗМЕННОСТЬ** *ж.* — 1. *геогр.* түбәнлек, инкү җир, инкүлек, үзән; 2. *перен. книж. презрит.* түбәнлек, кабахәтлек.

**НИ'ЗМЕННЫЙ** — 1. *геогр.* инкү (җир), уйсу; 2. *перен. книж. презрит.* түбән.

**НИЗОВО'Й** — 1. түбәнлекләрдә ...-а торган, түбән җирләрдә ...-а торган, уйсу җирләрдә ...-а торган; *низовая трава* — түбән җирләрдә үсә торган үлән; 2. елга тамагына якын урнашкан; *низовые города* — елга тамагына якын урнашкан шәһәрләр; 3. түбәннән искән (исә торган), елга тамагыннан искән (исә торган); *низовой ветер* — елга тамагыннан (түбәннән) исә торган җил; 4. башлангыч, түбәнге, урындагы; *низовые организации* — башлангыч оешмалар.

**НИЗО'ВЬЕ** *ср.* — түбән өлеш, түбән агым; *низовье Волги* — Волганың түбән өлеше.

**НИЗОЙТИ'** *сов. книж. устар.* — к. нисходить.

**НИЗО'К** *м. разг.* — 1. түбән өлеше, асты; *низок ящика* — ящикның асты; 2. *простореч. устар.* түбәнге каттагы трактир (кибет).

**НИ'ЗОМ** *нареч. разг.* — астан, түбән юл белән, аскы юл белән.

**НИ'ЗОСТЬ** *ж. книж.* — түбәнлек, кабахәтлек.

**НИЗРИ'НУТЬ** *сов. книж. ритор.* — төшерү, бәреп төшерү.

**НИЗРИ'НУТЬСЯ** *сов. книж. ритор.* — ташлану; *низринуться со скалы* — кыядан ташлану.

**НИ'ЗШИЙ** — 1. *(самый низкий)* иң түбәнге; 2. *книж.* түбән төзелешле, садә; *низший тип животных* — түбән төзелешле хайваннар; 3. түбән; *низшая культура* — түбән культура; 4. *офиц. устар.* башлангыч; *низшая школа* — башлангыч мәктәп.

**НИКА'К** I *нареч.* — ничек тә, берничек тә, һич тә. ◇ **Никак нельзя** — ярамый. **Никак нет** *устар.* — юк.

**НИКА'К** II *ввод. сл. разг.* — ахрысы, бугай, күрәсең, булса кирәк; *никак, это он пришёл* — ул килде, ахрысы.

**НИКАКО'Й** *местоим.* — 1. бернинди дә, һичбер төрле; *нет никаких затруднений* — һичбер төрле авырлыклар юк; *никакой он мне не родственник, а знакомый* — ул миңа бернинди дә кардәш түгел, танышым гына; 2. *разг. фам. пренебр. (никуда не годный)* бернәрсәгә дә яраксыз, бер нигә яраксыз, нигә дә ярамый торган. ◇ **И никаких гвоздей или и никаких** — к. гвоздь.

**НИКЕЛИРОВА'ТЬ** *сов. и несов.* — никель йөгертү.

**НИКЕЛИРОВА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — никель йөгертелү.

**НИКЕЛИРО'ВЩИК** *м.* — никелировщик, никель йөгертүче.

**НИ'КЕЛЬ** *м.* — никель (көмешсыман ак металл).

**НИ'КЛЫЙ** *редко* — шиңгән, сулган.

**НИ'КНУТЬ** *несов.* — 1. бөгелү, иелү, салыну; 2. *перен.* бетү; кимү, кими бару.

**НИКОГДА'** *нареч.* — һичбер вакытта да, беркайчан да. ◇ **Как никогда** — бервакытта да булмаган дәрәҗәдә (шикелле).

**НИКО'Й** *старин.*: **никоим образом, ни в коем случае** — һичбер хәлдә дә, әллә нигә дә.

**НИКОЛА'ЕВКА** *ж. истор. разг.* — николаевка (Николай II заманындагы кәгазь акча).

**НИКОТИ'Н** *м. мн.* нет — никотин (тәмәкедә була торган наркотик матдә).

**НИКОТО'РЫЙ** *разг.* — берәве дә, берсе дә.

**НИКТО'** *местоим.* — беркем дә, һичкем, берәү дә. ◇ **Никто иной, никто другой** (кроме) — башка берәү дә, аннан башка һичбер кем. **Никем никого** *обл.* — һичбер кем, һичкем, берәү дә, беркем дә.

**НИКУДА'** *нареч.* — 1. һичкая, беркая да; *никуда не пойду* — беркая да бармыйм; 2. бернигә дә, бернәрсәгә дә; *никуда не годится* — бернәрсәгә дә ярамый.

**НИКУДЫ'ШНЫЙ** *просторeч.* — бернәрсәгә яраксыз, бернәрсәгә дә ярамый торган.

**НИКЧЁМНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *разг.* — файдасызлык, файдасыз булу, яраксызлык, яраксыз булу.

**НИКЧЁМНЫЙ** и реже **НИКЧЕ'МНЫЙ** *разг.* — файдасыз, кирәксез, яраксыз, бернигә дә яраксыз, бернәрсәгә дә ярамый торган.

**НИМА'ЛО** *нареч. книж.* — һич тә, аз гына да.

**НИОТКО'ЛЕ** *устар. книж.* и **НИОТКО'ЛЬ** *устар. разг. нареч.* — к. ниоткуда.

**НИОТКУ'ДА** *нареч.* — һичкайдан, бер җирдән дә.

**НИПОЧЁМ** *нареч. разг.* — 1. *просторeч.* бөтенләй бушка, юк бәягә, бик арзан; *продал нипочём* — юк бәягә (бөтенләй бушка) саткан; 2. берни дә тормый, берни дә түгел; *ему нипочём поднять 50 кг* — анар 50 *кг* ны күтәрү берни дә түгел; 3. *просторeч.* әллә нигә дә.

**НИСКО'ЛЬКО** *нареч.* — бер дә, һич (тә), һичбер.

**НИСПАДА'ТЬ** *несов. книж. поэт.* — 1. *(падать вниз)* төшү, түбән төшү; 2. *(свешиваться)* салынып тору, салынып төшү, салынып төшеп тору.

**НИСПА'СТЬ** *сов. устар.* — 1. к. ниспадать 1; 2. салынып төшү.

**НИСПОСЛА'ТЬ** *сов. книж. устар. церк.* и *торж.* — иңдерү, күктән (югарыдан) иңдерү.

**НИСПОСЫЛА'ТЬ** *несов. книж. устар. церк.* и *торж.* — к. ниспослать.

**НИСПОСЫЛА'ТЬСЯ** *несов. страд. книж. устар. церк.* и *торж.* — иңдерелү, күктән (югарыдан) иңдерелү.

**НИСПРОВЕРГА'ТЬ** *несов. книж.* — к. ниспровергнуть.

**НИСПРОВЕРГА'ТЬСЯ** *несов. страд. книж.* — 1. ватып төшерелү, аударып төшерелү; 2. *перен.* төшерелү, бәреп төшерелү.

**НИСПРОВЕ'РГНУТЬ** *сов. устар.* — 1. ватып төшерү, аударып төшерү; 2. *перен.* бәреп төшерү; *ниспровергнуть самодержавие* — самодержавиене бәреп төшерү; 3. *перен.* төшерү; *ниспровергнуть авторитет* — авторитетны төшерү.

**НИСПУСКА'ТЬ** *несов. книж. поэт. устар.* — к. ниспустить.

**НИСПУСКА'ТЬСЯ** *несов. книж. поэт. устар.* — 1. к. ниспуститься; 2. *страд.* төшерелү, иңдерелү.

**НИСПУСТИ'ТЬ** *сов. книж. поэт. устар.* — төшерү, иңдерү.

**НИСПУСТИ'ТЬСЯ** *сов. книж. поэт. устар.* — төшү, иңү.

**НИСХОДИ'ТЬ** *несов. книж. поэт. устар.* — төшү, иңү.

**НИСХОДЯ'ЩИЙ** — 1. *поэт. устар.* төшә торган, иңә торган, төшүче, иңүче; 2. *мат.* (зурдан кечкенәгә таба) кимеп бара торган, кимеп баручы.

**НИТЕВИ'ДНЫЙ, НИТЕОБРА'ЗНЫЙ** *спец.* — җепсыман, җептәй.

**НИ'ТКА** *ж.* — 1. җеп; *шёлковые нитки* — ефәк җеп; 2. бер тезмә; *нитка жемчуга* — бер тезмә энҗе. ◇ **Вытянуть в нитку** *разг.* — тигез сафка тезү. **Вытянуться в нитку** — 1. тигез сафка тезелү; 2. ябыгу; 3. җан бирү (бернәрсәне дә кызганмау); *я рада для тебя в нитку вытянуться* (А. Островский) — мин синең өчен җанымны да бирергә риза. **По нитке** *разг.* — типтигез итеп. **Шито белыми нитками** *разг.* — ак җеп белән тегелгән, җепнең очы күренеп тора (серен ачуы кыен түгел, сизелепбеленеп тора). **На живую нитку** — к. живой. **Промокнуть до (последней) нитки** *разг.* — манма су булу. **До (последней) нитки** *разг.* — һичбер нәрсәне калдырмыйча, энәсеннән җебенә кадәр.

**НИ'ТОЧКА** *ж.* — нечкә җеп, кыска җеп. ◇ **Ходить по ниточке** *разг.* — биеп кенә тору (һәр сүзне, йомышны тыңлау). **По ниточке разобрать** *перен. разг.* — энәсеннән җебенә кадәр тикшерү, җентекләп тикшерү. **На ниточке висеть** — к. висеть.

**НИ'ТОЧНИК** *м.*, **НИ'ТОЧНИЦА** *ж. спец.* — җепче, җеп производствосы эшчесе.

**НИТЧА'ТКА** *ж.* — 1. *биол.* бака ефәге; 2. *зоол.* җеп суалчан (кеше һәм хайваннар эчендә яши торган паразит суалчан).

**НИ'ТЧАТЫЙ** — 1. *устар.* к. нитяный; 2. *спец.* җепсыман.

**НИТЬ** *ж.* — 1. *(нитка)* җеп; 2. җепсел; *нервные нити* — нерв җепселләре; 3. *перен.* тезмә; *нить воспоминаний* — истәлекләр тезмәсе. ◇ **Нить (разговора)** — сүзнең очы; *потерять нить (разговора)* — сүзнең очын югалту. **Держать все нити дела в своих руках** — бөтен эшне (эшнең бөтен очларын) үз кулында тоту. **Их соединяют нити дружбы** — аларны дуслык берләштерә. **Нити интриги** — интрига юллары. **Красной нитью (проходить)** *книж.* — кызыл җеп булып үтү (нинди дә булса бер фикернең эзлекле рәвештә үткәрелүе, ачык аңлашылуы, ярылып ятуы).

**НИ'ТЯНКА** *ж. разг.* — киҗе-мамык перчатка.

**НИ'ТЯНЫЙ** — җептән бәйләнгән, җеп...; *нитяные перчатки* — җептән бәйләнгән перчаткалар.

**НИЦ** *нареч. книж. устар.* — йөзтүбән.

**НИЧЕГО'** *нареч. разг.* — 1. зарар юк; *простите, я вас толкнул, кажется!* — *Ничего!* — гафу итегез, мин сезгә бәрелдем бугай! — Зарар юк! 2. барыбер; *деньги все*

*вышли, а ему ничего* — бер тиен акча калмаган, ә аңа барыбер; **3.** ярыйсы гына; *живёт ничего себе* — ярыйсы гына тора; 4. ярый, ярар; *пусть придёт, ничего* — ярый, килә бирсен. ◇ **Ничего подобного** *разг.* — һич тә алай түгел. **Ничем ничего** *обл.* — бернәрсә дә.

**НИЧЕГОНЕДЕ'ЛАНИЕ** *ср. мн.* нет, *разг.* — эшсезлек, эшсез яту, тик яту, буш йөрү, түшәмгә төкереп яту.

**НИЧЕГО'ШЕНЬКИ** *разг. фам.* — бер генә нәрсә дә; *ничегошеньки не поняла* — бер генә нәрсә дә аңламады.

**НИЧЬЕ'Й** *местоим.* — **1.** һичбер кешенең кемнең дә; *не презирай совета ничьего* — һичбер кешенең киңәшен читкә какма; 2. *в знач. сказ.* берәүнеке дә түгел, беркемнеке дә түгел; *эти вещи ничьи* — бу әйберләр беркемнеке дә түгел.

**НИЧЕ'ЙНЫЙ** *спорт.* — ничьяга ...-ган; *ничейная партия* — ничьяга беткән партия.

**НИЧКО'М** *нареч. разг.* — йөзтүбән.

**НИЧТО'** *ср. местоим. отриц.* — **1.** һичбер нәрсә, һични, һичнәрсә, бернәрсә дә; 2. *перен. в знач. сущ.* к. ничтожество. ◇ **Ничто иное, ничто другое** (кроме) — башка бернәрсә дә, аннан башка бернәрсә дә.

**НИЧТО'ЖЕСТВО** *ср. книж.* — **1.** кечкенәлек, азлык; **2.** түбәнлек. әһәмиятсезлек; 3. түбән кеше; 4. әһәмиятсез әйбер.

**НИЧТО'ЖИТЬ** *несов. книж. устар.* — 1. *(уничтожать)* бетерү, һәлак итү; 2. *(унижать)* кимсетү, түбәнәйтү, түбәнсетү.

**НИЧТО'ЖНОСТЬ** *ж. книж.* — к. ничтожество.

**НИЧТО'ЖНЫЙ** — 1. *(очень малый)* бик аз, бик кечкенә; 2. *(совершенно незначительный)* бик түбән, бик вак, әһәмиятсез.

**НИЧУ'ТЬ** *нареч. разг.* — к. нисколько. ◇ **Ничуть не бывало** *разг.* — һич тә юк, бер дә юк, юк.

**НИ'ША** *ж.* — ниша, куыш (бизәү әйберләре, статуялар яки кровать, шкаф кую өчен стенага ясала торган куыш).

**НИШКНУ'ТЬ** *сов.*: нишкни! — тик тор! эндәшмә!

**НИШТО'** *нареч. обл.* — **1.** сүз әйтерлек түгел; *ништо, хороший парень* — сүз әйтерлек түгел, яхшы егет; 2. *в знач. сказ.* шулай кирәк тә; *и ништо ему, что побили* — кыйнаганнар икән, шулай кирәк тә аңар.

**НИЩА'ТЬ** *несов.* — ярлылану, фәкыйрьлеккә төшү, хәерчелеккә төшү, мохтаҗлыкка калу; бөлү.

**НИ'ЩЕНКА** *ж.* — теләнче хатын-кыз.

**НИ'ЩЕНСКИЙ** — 1. теләнче...-ы, хәерче...-ы; *нищенская сума* — теләнче (хәерче) капчыгы; 2. *перен. разг. (очень малый)* бик кечкенә, бик вак, бик аз.

**НИ'ЩЕНСТВО** *ср. мн.* нет, *книж.* — 1. теләнчелек, хәерчелек; *в Советской стране нищенство ликвидировано* — Советлар илендә хәерчелек бетерелде; 2. *(крайняя бедность)* ярлылык, фәкыйрьлек, зур мохтаҗлык.

**НИ'ЩЕНСТВОВАТЬ** *несов. книж.* — 1. *(собирать подаяние)* хәер өстәү, соранып йөрү; 2. *(жить в нищете)* мохтаҗлыкта яшәү, фәкыйрьлектә яшәү.

**НИЩЕТА'** *ж. мн.* нет — 1. *(крайняя бедность)* зур мохтаҗлык, фәкыйрьлек; 2. *собир.* хәерчеләр, теләнчеләр.

**НИ'ЩИЙ** — 1. *(крайне бедный)* бик ярлы, фәкыйрь, мохтаҗ; 2. *в знач. сущ.* хәерче, теләнче. ◇ **Нищая братия** *нар.-поэт.* — теләнчеләр, хәерчеләр.

**НО I** *противит. союз* — ләкин, әмма.

**НО II** — на-а-а! (ат куу ымлыгы).

**НО'БИЛИ** *м. мн.* нет, *истор.* — нобильләр (борынгы Римда һәм урта гасырда Венеция республикасында һ. б. кайбер республикаларда аристократларны, аксөякләрне шулай атаганнар).

**НОБИЛИТЕ'Т** *м. мн.* нет, *собир. истор.* — нобильләр.

**НОВА'ТОР** *м. книж.* — новатор (яңалык кертүче).

**НОВА'ТОРСКИЙ** *книж.* — новаторлык ...-ы; новаторчылык ...-ы; *новаторские идеи* — новаторлык идеяләре.

**НОВА'ТОРСТВО** *ср. мн.* нет, *книж.* — 1. *(нововведения)* новаторлык, яңалыклар; 2. *(деятельность новатора)* новаторчылык.

**НОВЕ'ЙШИЙ** — 1. *(самый новый)* өр-яңа, иң яңа; 2. *(последний по времени)* иң соңгы.

**НОВЕ'ЛЛА** *ж.* — новелла (1. *литер.* кечкенә әсәр, хикәя; 2. *право* нинди дә булса закон җыентыгына, уставка һ. б. кертелгән иң соңгы өстәмә).

**НОВЕЛЛИ'СТ** *м.* — новеллалар язучы.

**НОВЕЛЛИСТИ'ЧЕСКИЙ** *лит.* — новеллистик; *новеллистическая литература* — новеллистик әдәбият.

**НОВЕ'ТЬ** *несов. редко* — яңару, яңара бару.

**НОВИЗНА'** *ж.* — яңалык.

**НОВИ'К** *м.* — яңа кеше (1. *истор.* Москва Русендә — дәүләт хезмәтенә яңа гына керешкән кеше; 2. *устар.* берәр хезмәткә яңа гына керешкән кеше).

**НОВИНА'** *ж. обл.* — **1.** к. новость; 2. *(целина)* чирәм җир, сөрелмәгән җир; 3. *(хлеб нового урожая)* яңа, яңа икмәк (шушы елда яңа өлгергән иген уңышы); 4. агартылмаган киндер (яңа гына тукылган киндер).

**НОВИ'НКА** *ж. разг.* — яңалык (яңа әйбер, яңа хәбәр). ◇ **В новинку** *разг.* — яңалык; *вам уже это надоело, а мне в новинку* — бу сезне туйдырган инде, ә минем өчен ул әле яңалык.

**НОВИЧО'К** *м. разг.* — **1.** яңа кеше; *он в торговле ещё новичок* — ул сәүдә эшендә яңа кеше әле; **2.** *(об ученике)* яңа укучы.

**НОВОБРА'НЕЦ** *м. дореволь.* — новобранец (яңа гына солдатка алынган кеше).

**НОВОБРА'ЧНАЯ** *ж.* — яңа гына кияүгә чыккан.

**НОВОБРА'ЧНЫЕ** *ед.* нет — яңа гына өйләнешкәннәр.

**НОВОБРА'ЧНЫЙ** *м.* — яңа гына өйләнгән.

**НОВОВВЕДЕ'НИЕ** *ср. книж.* — яңалык.

**НОВОВВЕДЁННЫЙ** *книж.* — яңа кертелгән.

**НОВОВЫ'СТРОЕННЫЙ** — яңа төзелгән, яңа салынган, яңа корылган.

**НОВОГО'ДНИЙ** — яңа ел ...-ы; яңа елга багышланган; *новогодний подарок* — яңа ел бүләге; *новогодний рассказ* — яңа елга багышланган хикәя.

**НОВОИЗОБРЕТЁННЫЙ** — яңа уйлап табылган.

**НОВОИСПЕЧЁННЫЙ** *разг. шутл.* — 1. яңа гына ...-п чыккан; *новоиспечённая книга* — яңа гына басылып чыккан китап; 2. яңа гына ... булган кеше; *новоиспечённый профессор* — яңа гына профессор булган кеше.

**НОВОЛУ'НИЕ** *ср.* — яңа ай; ай башы.

**НОВОМО'ДНЫЙ** — 1. яңа мода буенча ...-ган; *новомодный костюм* — яңа мода буенча тегелгән костюм; 2. *перен. неодобр.* яңа гына модага кереп киткән; *новомодные словечки* — яңа гына модага кереп киткән сүзләр.

**НОВОНАРЕЧЕ'ННЫЙ** *книж.-церк.* — яңа гына исем бирелгән, ат кушылган.

**НОВОНАСЕЛЁННЫЙ** — яңа гына халык утырган; *новонаселённый пункт* — яңа гына халык утырган җир.

**НОВООБРАЗОВА'НИЕ** *ср. книж.* и *спец.* — 1. беренче мәртәбә барлыкка килү; *процесс новообразования* — беренче мәртәбә барлыкка килү процессы; 2. беренче мәртәбә барлыкка килгән форма (элемент һ. б.).

**НОВООБРАЩЁННЫЙ** *книж.-ирон.* — әле генә яңа фикер (караш) үзләштергән.

**НОВООТКРЫ'ТЫЙ** — яңа гына ачылган, яңа гына табылган.

**НОВОПОСЕЛЕ'НЕЦ** *м.*, **НОВОПОСЕЛЕ'НКА** *ж. офиц.* — яңа күчеп килгән кеше.

**НОВОПРЕСТА'ВЛЕННЫЙ** *церк.* — күптән түгел үлгән, күптән түгел вафат булган.

**НОВОПРИБЫ'ВШИЙ** — яңа гына килгән, яңа гына кайткан.

**НОВОРОЖДЁННЫЙ** — яңа туган (бала).

**НОВОСЁЛ** *м.*, **НОВОСЁЛКА** *ж. обл.* — яңа урынга күчеп тора башлаган кеше.

**НОВОСЕ'ЛЬЕ** *ср. мн.* нет — 1. *(новое жилище)* яңа йорт, яңа өй; 2. өй котлау мәҗлесе, квартира котлау мәҗлесе.

**НОВОСТРО'ЙКА** *ж.* — яңа корылма, яңа корылыш, яңа төзелеш; *новостройки коммунизма* — коммунизмның яңа төзелешләре.

**НО'ВОСТЬ** *ж.* — яңалык; яңа хәбәр. ◇ **Это что ещё за новость?** — бу ни дигән сүз тагын? **Вот новости!** — менә сиңа кирәк булса!

**НОВОТЕ'ЛЬНЫЙ** *с.-х.* — яңа бозаулаган; беренче тапкыр бозаулаган.

**НОВОЯ'ВЛЕННЫЙ** *церк.* и *книж. ирон.* — яңа гына барлыкка килгән.

**НО'ВШЕСТВО** *ср. книж.* — яңалык.

**НО'ВЫЙ** — яңа. ◇ **Новый свет** *устар.* — яңа дөнья (иске дөньядан — Европа, Азия, Африкадан — соң ачылганга күрә шартлы рәвештә Американы шулай атаганнар). **Новая экономическая политика** — к. нэп.

**НОВЬ** *ж. мн.* нет, *с.-х.* — 1. *(целина)* чирәм җир, сөрелмәгән җир; 2. *обл. (хлеб нового урожая)* яңа, яңа ашлык (шушы елда яңа өлгергән иген уңышы).

**НОГА'** *ж.* — аяк. ◇ **Идти (нога) в ногу** — бер аяктан атлау. **Сбиться с ноги** *воен.* — аякны ялгыштыру. **Дать ногу** *воен.* — бер аяктан атлау. **Стать на ноги** *разг.* — 1. төзәлү, аякка басу; 2. үз алдына яшәрлек булу. **Стоять на ногах** — үз алдына яши алу. **Сбиться с ног** — аяктан егылу. **Со всех ног** *разг.* — җан-фәрманга (бик ашыгып, бик тиз). **Давай бог ноги** *разг. шутл.* — таю, сызу, табан ялтырату (бик тиз качып китү). **На широкую (барскую, большую) ногу** — иркенлектә, муллыкта, байларча. **На короткой (дружеской) ноге** — бик дус, тату, агай-энеләрчә. **Сойтись на короткую (дружескую) ногу** — дуслашып китү. **Поставить на ноги** *разг.* — аякка бастыру (1. дәвалап терелтү; 2. тәрбияләп үстереп җиткерү, үз алдына дөнья көтәрлек хәлгә җиткерү). **На ногах** — 1. аягүрә; *все были на ногах, сидели только двое* — барысы да аягүрә басканнар, ике кеше генә утырып тора иде; 2. аяк өстендә; *он перенёс болезнь на ногах* — ул авыруны аяк өстендә үткәрде; *чуть свет уж на ногах* — таң тишегеннән ул инде аяк өстендә. **Нога за ногу идти** *разг.* — аякларны сөйрәп бару (акрын бару). **Едва ноги носят** *разг.* — көчкә йөрим (йөрисең...). **Одной ногой в могиле** *разг.* — бер аягы белән кабердә; бер аягы җирдә, бер аягы гүрдә. **Валяться в ногах** *разг.* — к. валяться. **В ногах** (кровати и т. п.) — аяк очында. **Без задних ног** — к. задний. **Без ног** *разг.* — аяксыз калдым (бик нык арыдым). **Поднять на ноги** *разг.* — аякка бастыру (куркытып). **Под ногами** — җирдә, идәндә. **Под ногами (вертеться, идти и т. п.)** — аяк астында буталып йөрү. **Вверх ногами** *разг.*, **кверх ногами** *просторечи.* — баш түбән. **Ноги не будет** *разг.* — аяк басмам, аяк бастырмам. **Ни ногой** *разг.* — аяк та басмау. **Ноги унести** *разг.* — качып китү. **Ног под собой не слышит от радости** — шатлыгыннан түбәсе түшәмгә тигән, түбәсе күккә тигән. **Протянуть ноги** — аяк сузу (үлү). **Ноги подкашиваются** — тез буыннары калтырый. **Наступить на ногу** — к. наступить.

**НОГА'ЙЦЫ** *мн.* — нугайлар (Төньяк Кавказда яшәүче халык).

**НОГОТО'К** *м.* — 1. кечкенә тырнак; 2. *бот.* тырнак гөл. ◇ **С ноготок** — бармак башы хәтле генә. **Мужичок с ноготок, борода с локоток** — үзе бер карыш, сакалы биш карыш.

**НО'ГОТЬ** *м.* — тырнак (кеше тырнагы). ◇ **До конца, до кончиков ногтей** *разг.* — чеп-чи; *бюрократ до конца ногтей* — чеп-чи бюрократ (ата бюрократ).

**НОГТЕВО'Й** — тырнак...-ы; *ногтевая щетка* — тырнак щёткасы.

**НОГТИ'СТЫЙ** *простореч.* — озын тырнаклы.

**НОГТОЕ'ДА** *ж. мн.* нет, *мед.* — тырнак асты үлекләү (авыру).

**НОЖ** *м.* — пычак. ◇ **Быть на ножах** *разг.* — пычакка пычак килеп тору (дошман булу). **Под ножом (умереть)** *разг.* — пычак астында үлү (операция ясаганда). **Без ножа зарезать** — к. зарезать. **Пристать с ножом к горлу** — к. горло.

**НОЖЕВО'Й** *спец. обл.* — пычак...-ы; *ножевой черенок* — пычак сабы.

**НО'ЖИК** *м.* — 1. кечкенә пычак; 2. *разг.* пычак. ◇ **Перочинный ножик** — пәке.

**НО'ЖКА** *ж.* — 1. тәпи, кечкенә аяк; 2. аяк; *ножка стола* — өстәл аягы; 3. *(у гриба)* сабак. ◇ **Подставить ножку** *разг.* — аяк чалу.

**НО'ЖНИЦЫ** *ед.* нет — 1. кайчы; 2. *перен. истор.* аерма.

**НОЖНО'Й** — аяк ...-ы, аяк белән эшләтелә торган (хәрәкәткә китерелә торган); *ножная машина* — аяк машинасы.

**НО'ЖНЫ** *ед.* нет — кыны.

**НОЖО'ВКА** *ж. спец.* — ножовка (бер тоткалы пычкы).

**НОЖО'ВЩИК** *м. спец.* — пычак остасы, пычаклар ясаучы мастер.

**НОЖО'ВЩИНА** *ж. разг. устар.* — пычаклар кулланып сугышу.

**НОЗДРЕВА'ТЫЙ** — тишекле, тишек-тишек, күзле-күзле.

**НОЗДРЕВИ'НА** *ж. спец.* — тишек, күз.

**НОЗДРЯ'** *ж.* — борын тишеге.

**НОКА'УТ** *м. спорт.* — нокаут (бокста ин көчле, каршы якны аяктан егарлык һәм шуннан соң тормаслык итеп сугу).

**НОЛЕВО'Й** — ноль ...-ы; *нолевая степень* — ноль дәрәҗәсе.

**НОЛЬ** и **НУЛЬ** *м.* — 1. *(цифра)* ноль; 2. *перен. разг.* әһәмиятсез (кеше); вак кеше, кечкенә кеше, ыбыр-чыбыр.

**НОМА'ДЫ** *м. мн. устар.* — күчмә халыклар.

**НОМЕНКЛАТУ'РА** *ж. книж.* — номенклатура, исемлек, исемнәр, терминнар җыентыгы (нинди дә булса бер эштә, мәсәлән, медицинада, телеграфта, географиядә һ. б. кулланыла торган исемнәр, терминнар җыентыгы).

**НОМЕНКЛАТУ'РНЫЙ** *спец.* — номенклатура ...-ы; *номенклатурный ярлык* — номенклатура ярлыгы.

**НО'МЕР** *м.* — номер.

**НОМЕРА'ТОР** *м.* — к. нумератор.

**НОМЕРА'ЦИЯ** *ж.* — к. нумерация.

**НОМЕРНО'Й** — 1. номер ...-ы; *номерной знак* — номер билгесе; 2. *спец.* гостиницада эшләүче, гостиница ...-ы; *номерной работник* — гостиница работнигы.

**НОМЕРОВА'ТЬ** *несов.* — номерлау, номерлар сугу.

**НОМИНА'Л** *м. спец.* — номинал (әйбернең өстендә күрсәтелгән бәясе).

**НОМИНА'ЛЬНЫЙ** — 1. *спец.* номиналь, (әйбернең) өстенә куелган; *номинальная цена* — номиналь бәя, (әйбернең) өстенә куелган бәясе; 2. *книж.* номиналь (исемен күтәреп, эшен эшләми торган); *номинальный руководитель дела* — эшнең номиналь җитәкчесе.

**НОМИНАТИ'ВНЫЙ** *лингв.* — атау ...-ы; *номинативная функция слова* — сүзнең атау функциясе.

**НОМИНА'ЦИЯ** *ж. книж. науч.* — атау.

**НОРА'** *ж.* — өн, җәнлек оясы.

**НОРВЕ'ЖКА** *ж.* — норвегияле хатынкыз.

**НОРВЕ'ЖСКИЙ** — норвегиялеләр ...-ы; *норвежский язык* — норвегиялеләр теле.

**НОРВЕ'ЖЦЫ** *мн. (ед.* норвежец) — норвегиялеләр, Норвегия халкы.

**НОРД** *м. мор.* — 1. *(северное направление)* төньяк; 2. *(северный ветер)* төньяк җиле. ◇ **Норд-вест** — 1. төньяк-көнбатыш; 2. төньяк-көнбатыш җиле. **Норд-ост** — 1. төньяк-көнчыгыш; 2. төньяк-көнчыгыш җиле.

**НОРИ'ЧНИК** *м. бот.* — сыраҗ.

**НО'РИЯ** *ж. тех.* — нория (соскылы элеватор).

**НО'РКА I** *ж.* — кечкенә оя, кечкенә өн.

**НО'РКА II** *ж. зоол.* — чәшке (көзәннәр семьялыгыннан кечкенә бер ерткыч җәнлек.)

**НО'РКОВЫЙ** — 1. чәшке...-ы; *норковый мех* — чәшке мехы; 2. чәшке мехыннан ...-ган; *норковый воротник* — чәшке мехыннан ясалган яка.

**НО'РМА** *ж.* — норма, күләм; *норма выпадения осадков* — явым-төшемнәр күләме; *перевыполнить дневную норму* — көнлек норманы арттырып үтәү.

**НОРМАЛИЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. книж.* — к. нормализовать.

**НОРМАЛИЗИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов.* — к. нормализоваться.

**НОРМАЛИЗОВА'ТЬ** *сов.* и *несов. книж.* — 1. нормалаштыру, нормага салу; 2. нормальләштерү, нормаль хәлгә китерү.

**НОРМАЛИЗОВА'ТЬСЯ** *сов.* и *несов. книж.* — 1. нормалашу, нормага салыну; 2. нормальләшү, нормаль хәлгә килү; 3. *страд.* нормалаштырылу, нормага салыну; нормальләштерелү, нормаль хәлгә китерелү.

**НОРМА'ЛЬНЫЙ** — 1. нормаль, гадәттәге; 2. *разг. (психически здоровый)* акыллы (психик яктан сау-сәламәт).

**НОРМА'ННЫ** *истор.* — норманнар (урта гасырларда Скандинавиядә яшәгән герман кабиләләренең гомуми исеме).

**НОРМАТИ'В** *м.* — норматив (эшләп чыгарылган яки тотылган әйбернең нинди дә булса бер берәмлеккә туры килә торган күләме, саны, нормасы).

**НОРМАТИ'ВНЫЙ** — норматив...; *нормативный запас* — норматив запас; *нормативная грамматика* — норматив грамма-

тика (тел нормаларын, кагыйдәләрен билгели торган грамматика).

**НОРМИРОВА'ТЬ** *сов.* и *несов.* — нормалаштыру, нормага кую, нормага салу.

**НОРМИРОВА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — нормалаштырылу, нормага куелу, нормага салыну.

**НОРМИРО'ВЩИК** *м. спец.* — нормировщик.

**НО'РОВ** *м. мн.* нет — 1. *устар. обл.* (*характер*) табигать, холык, характер; гадәт; 2. *простореч.* (*упрямство*) тискәрелек, үз сүзлелек, кирелек. ◇ **Лошадь с норовом** — чыгымчы ат.

**НОРОВИ'СТЫЙ** *простореч.* — 1. начар холыклы, кире, тискәре, үз сүзле; 2. (*о лошади*) чыгымчы.

**НОРОВИ'ТЬ** *несов. разг.* — тырышу; *норовить угодить* — ярарга тырышу.

**НОС** *м.* — борын. ◇ **Нос к носу** или **носом к носу** *разг. фам.* — к. лицо. **Под носом** *разг.* — борын астында, бик якында. **С носу** *простореч.* — кеше башыннан. **На носу** *разг.* — борын төбендә (житеп килә); *зима на носу* — кыш борын төбендә (кыш житеп килә). **С носом (остаться, быть)** *разг.* — алдану. **(Оставить) с носом** *разг.* — алдау. **Не по носу** *простореч.* — ошамый. **Говорить (произносить) в нос** *разг.* — борын аша сөйләү; тыңкыш сөйләү. **Водить за нос** *разг.* — алдап йөртү. **Не видеть дальше своего носа** *разг.* — борын астыннан ары күрмәү. **Повесить нос (на квинту)** *разг.* — борын салындыру. **Задрать (поднять) нос** *разг.* — борын күтәрү. **Совать (сунуть) нос, соваться (сунуться) с носом** *разг.* — (һәр эшкә) тыгылу, борын тыгу. **Утереть нос** — уздыру. **Уткнуть нос, уткнуться носом** *разг.* — борынын төртү; *уткнулся носом в книгу* — китапка борынын төрткән. **Натянуть нос, наклеить (наставить, налепить) нос** *разг. фам.* — алдау. **Показать нос** *разг.* — 1. мыскыл итеп борын күрсәтү; 2. күренү. **Держать нос по ветру** — обстановкага җайлашу. **Клевать носом** — к. клевать. **Зарубить на носу** — истә тоту.

**НОСА'К** *м. спец.* — грузчик.

**НОСА'СТЫЙ** *простореч.*, **НОСА'ТЫЙ** *разг.* — зур борынлы.

**НОСА'Ч** *м.* — 1. *разг.* зур борынлы кеше; 2. *зоол.* борынлач (маймыл).

**НО'СИК** *м.* — 1. кечкенә борын; 2. томшык; 3. борын (чәйнек, кувшин, сөт савыты һ. б. борыны).

**НОСИ'ЛКИ** *ед.* нет — носилка.

**НОСИ'ЛЬНЫЙ** — өскә киелә торган.

**НОСИ'ЛЬЩИК** *м.* — носильщик.

**НОСИ'ТЕЛЬ** *м*, **НОСИ'ТЕЛЬНИЦА** *ж. книжн.* — 1. ия, вәкил, таратучы; *носители новой социалистической культуры* — яңа социалистик культура ияләре (таратучылар); 2. *мед. биол.* таратучы, йоктыручы (авыру таратучы); *носитель дифтерии* — дифтерия авыруы таратучы; 3. сөйләшүче; *носитель английского языка* — инглиз телендә сөйләшүче кеше.

**НОСИ'ТЬ** *несов.* — 1. йөртү, күтәреп йөртү, күтәреп йөрү; 2. ташу; *воду носить* — су ташу; 3. очыру, очырып йөртү; *ветер носит сухие листья* — җил коры яфракларны очыра; 4. кию, киеп йөрү; *носить военную форму* — хәрби форма кию (киеп йөрү); 5. йөрү; *она носит фамилию мужа* — ул иренең фамилиясендә йөри; 6. дип йөртелү, дип йөртү; *аммиачная вода носит название нашатырного спирта* — аммиаклы суны нашатырь спирты дип йөртәләр; 7. күтәрү; *носить ребёнка* — бала күтәрү (йөкле булу). ◇ **Экономические законы носят объективный характер** — экономик законнар объектив характерда була. **Спор носил бурный характер** — бәхәс бик кызу характерда булды, бәхәс бик кызу барды. **Носить на руках** *перен.* — уч төбендә генә йөртү (бик иркәләү). **Куда тебя носит каждый день?** — көн саен син кая барасың (йөреп торасың)?

**НОСИ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. йөрү; 2. очып йөрү; *по воздуху носятся шмели* — һавада төкле туралар очып йөри; 3. *разг.* мавыгып йөрү; *носиться с новым проектом* — яңа проект белән мавыгып йөрү; 4. *разг. пренебр.* ис китеп йөрү; *носится со своим сыном* — улына исе китеп йөри; 5. киелү, чыдау, түзү; *бостоновый костюм долго носится* — бостон костюм озак киелә, бостон костюм озакка чыдый.

**НО'СКИЙ** — 1. *разг.* (*об одежде, обуви*) нык, чыдам; 2. *спец.* (*о птице*) күп йомырка сала торган.

**НО'СКОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. ныклык, чыдамлык; 2. (*о птице*) йомырка салу.

**НОСОВИ'К** *м.* — 1. *разг.* борын авыруларын дәвалаучы врач; 2. *обл.* кулъяулык.

**НОСОВО'Й** — 1. борын...-ы; *носовые болезни* — борын авырулары; 2. *лингв.* борынлаштырылган; *носовые гласные* — борынлаштырылган сузыклар. ◇ **Носовой платок** — кулъяулык.

**НОСОГЛО'ТКА** *ж. анат.* — йоткылык өсте.

**НОСОГРЕ'ЙКА** *ж. разг.* — тәмәке трубкасы.

**НОСО'К I** *м.* — 1. *разг.* кечкенә борын; 2. баш, оч; *ботинки с узкими носками* — очлы башлы ботинка; *ударить мяч носком* — тупка аяк очы белән тибү.

**НОСО'К II** *м. разг.* — сыңар оекбаш.

**НОСОРО'Г** *м. зоол.* — борынмөгез, кәркадән.

**НОСТАЛГИ'Я** и **НОСТАЛЬГИ'Я** *ж. книжн.* — җирсү, туган илне сагыну.

**НО'ТА I** *ж.* — 1. *муз.* нота; 2. *перен.* тон, тавыш; *нота неудовольствия* — канәгатьсезлек тоны. ◇ **Как по нотам** *разг.* — шоп-шома, ул-бусыз (тоткарсыз); *всё прошло, как по нотам* — барысы да шоп-шома үтте дә китте.

**НО'ТА II** *ж. полит.* — нота (бер ил хөкүмәтенең икенче ил хөкүмәтенә җибәргән дипломатик мөрәҗәгате).

**НОТАБЕ'НА** *ж.*, **НОТАБЕ'НЕ** *нескл.* — нотабена (укучының игътибарын юнәлдерү өчен куела торган билге — NB билгесе).

**НОТАРИА'ЛЬНЫЙ** *офиц.* — 1. нота-

риус ...-ы; нотариаль; *нотариальная контора* — нотариаль контора; 2. нотариуста таныкланган; *нотариальный акт* — нотариуста таныкланган акт.

**НОТА'РИУС** *м.* — нотариус (актларны, килешү кәгазьләрен, документларның копияләрен һ. б. ларны официаль рәвештә таныклап торучы кеше).

**НОТА'ЦИЯ I** *ж. разг.* — үгет, нәсихәт.

**НОТА'ЦИЯ II** *ж. спец.* — нотация (теге я бу өлкәдә кулланыла торган шартлы билгеләр).

**НОТИФИЦИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. дипл.* — нота җибәрү.

**НО'ТНИЦА** *ж.* — ноталар китапханәсе.

**НО'ТНЫЙ** — нота ...-ы; *нотная бумага* — нота кәгазе.

**НОТОПЕЧА'ТАНИЕ** *ср. мн.* нет — ноталар басу, ноталар бастыру.

**НОТОПЕЧА'ТНЯ** *ж.* — нотопечатня (ноталар баса торган типография яки литография).

**НОЧЕВА'ТЬ** *сов.* и *несов.* — куну. ◇ **Дневать и ночевать** — көне-төне ...-да булу, бөтен вакытны...-да үткәрү; *дневать и ночевать в поле* — көне-төне басуда булу.

**НОЧЛЕ'Г** *м.* — 1. куну урыны; *обеспечить приезжающих ночлегом* — килүчеләрне куну урыны белән тәэмин итү; 2. куну; *расположиться на ночлег в лесу* — урманда кунарга урнашу.

**НОЧЛЕ'ЖКА** *ж. простореч. устар.* — ночлежка (тору урыннары булмаган шәһәр ярлылары өчен куну йорты).

**НОЧЛЕ'ЖНИК** *м.*, **НОЧЛЕ'ЖНИЦА** *ж.* — 1. *простореч. устар.* кунучы; 2. ночлежкада кунучы, ночлежник.

**НОЧЛЕ'ЖНИЧАТЬ** *несов. простореч.* — куну, кунарга туктау.

**НОЧНИ'К** *м.* — төнге лампа (төн буена яндырыла торган кечкенә лампа).

**НОЧНИ'ЦА** *ж. зоол.* — ябалакчык (күбәләк).

**НОЧНО'Е** *ср. мн.* нет: **отправиться в ночное** — (ат ашатырга) куна бару.

**НОЧНО'Й** — төнге. ◇ **В ночное время** — төнлә.

**НОЧЬ** *ж.* — төн. ◇ **Покойной ночи, спокойной ночи** — тыныч йокы. **Белая ночь** — к. белый. **День и ночь** — көне-төне.

**НО'ЧЬЮ** *нареч.* — төнлә, төнен. ◇ **Днём и ночью** — көне-төне.

**НО'ША** *ж.* — йөк.

**НО'ЩНО** *нареч.*: **денно и нощно** — көне-төне.

**НО'ЮЩИЙ** — сызлап ..., сызлый торган; *ноющая боль* — сызлап авырту.

**НОЯ'БРЬ** *м.* — ноябрь.

**НОЯ'БРЬСКИЙ** — ноябрь ...-ы, ноябрь аендагы; *ноябрьские дожди* — ноябрь аендагы яңгырлар.

**НРАВ** *м.* — 1. *(характер)* табигать, холык, характер; 2. *только мн.* *(обычай)* гореф-гадәтләр, йолалар. ◇ **По нраву** *разг.* — ошый.

**НРА'ВИТЬСЯ** *несов.* — 1. *(производить хорошее впечатление)* ошау, күңелгә ошау, күңелгә яту; 2. *безл.* ярату; *ему нравится ездить верхом* — ул ат өстендә йөрергә ярата.

**НРА'ВНЫЙ** *простореч.* — кырыс, тар холыклы.

**НРАВООПИСА'НИЕ** *ср. устар.* — гореф-гадәтләрне, көнкүрешне тасвирлау (нинди дә булса бер халыкның яки җәмгыять катлавының).

**НРАВООПИСА'ТЕЛЬНЫЙ** — гореф-гадәтләрне, көнкүрешне тасвирлый (чагылдыра) торган.

**НРАВОУЧЕ'НИЕ** *ср. книж.* — үгет-нәсихәт.

**НРАВОУЧИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.* — үгет-нәсихәтле.

**НРА'ВСТВЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — әхлаклылык, әхлак. ◇ **Нравственность его побуждений внушает сомнения** — аның теләкләренең сафлыгына ышанып җитеп булмый.

**НРА'ВСТВЕННЫЙ** *книж.* — 1. әхлаклы; *нравственный человек* — әхлаклы кеше; 2. мораль, рухи; *нравственный подъём* — рухи күтәренкелек.

**НУ** *разг.* — 1. *межд.* я! я... лә! *ну, скорей!* — я, тизрәк! я, тизрәк лә! 2. я ... соң; *ну, не совестно ли вам?* — я, оят түгелме соң сезгә? 3. ну; *ну и артист же!* — ну артист та соң! 4. китсәнә! булмас ла! *я сегодня уезжаю* — *Ну?* (*Да ну?*) — мин бүген китәм. — Булмас лә! ◇ **Ну и ну!** — ай-һай, исең китәр! **Ну тебя!** — борчып йөрмә әле, кит әле моннан! **Ну его!** — бер тиенгә кирәге юк!

**НУВЕЛЛИ'СТ** *м.* — к. новеллист.

**НУ'ДИТЬ** *несов. устар.* — ирексезләү, мәҗбүр итү.

**НУ'ДНЫЙ** *разг.* — эч пошыргыч, күңелсез, ялыктыргыч.

**НУЖДА'** *ж.* — 1. *(бедность)* мохтаҗлык, ярлылык, фәкыйрьлек; 2. кирәк, йомыш, ихтыяҗ, хаҗәт; *для нужд транспорта* — транспорт кирәкләре өчен. ◇ **Нужды нет или нет нужды** — зарар юк.

**НУЖДА'ЕМОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — мохтаҗлык, ярлылык, фәкыйрьлек.

**НУЖДА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. мохтаҗлыкта яшәү, фәкыйрьлектә яшәү; *сильно нуждаться* — бик зур мохтаҗлыкта яшәү; 2. мохтаҗ булу, кирәксенү; кирәк булу; *ни в чём не нуждаться* — һичбер нәрсәгә мохтаҗ булмау; *больной нуждается в свежем воздухе* — авыруга саф һава кирәк.

**НУЖНИ'К** *м. простореч.* — бәдрәф.

**НУ'ЖНО** — кирәк, тиеш.

**НУ'ЖНЫЙ** — кирәкле, кирәк.

**НУ'-КА** *межд. разг.* — я әле.

**НУ'-КАСЬ, НУ'-КАСЯ** *простореч.* — к. ну-ка.

**НУЛЕВО'Й** — к. нолевой.

**НУЛЛИФИЦИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. книж. спец.* — к. аннулировать.

**НУЛЬ** *м.* — к. ноль. ◇ **Сводиться (свестись) к нулю** — юкка чыгу, әһәмиятен югалту.

**НУ'МЕР** *м.* — к. номер.

**НУМЕРА'ТОР** *м. спец.* — нумератор

(1. тәртип номеры баса торган аппарат; 2. электр звоногында кайдан шалтыратуны күрсәтә торган җайланма; 3. бәләкәй телефон коммутаторы).

**НУМЕРА'ЦИЯ** *ж. книж.* — 1. к. номеровать; 2. номерлар; *нумерация страниц* — бит номерлары; 3. *мат.* нумерация (саннарның исеме һәм язылышы).

**НУМЕРОВА'ТЬ** — к. номеровать.

**НУМИЗМА'Т** *м.* — нумизмат (1. нумизматика белән шөгыльләнүче; 2. борынгы акчалар һәм медальләр җыючы).

**НУМИЗМА'ТИКА** *ж. мн.* нет — нумизматика (борынгы акчаларны һәм медальләрне өйрәнә торган фән).

**НУМИЗМАТИ'ЧЕСКИЙ** — 1. нумизматика ...-ы; нумизматик; *нумизматический кабинет* — нумизматика кабинеты; 2. иске акчалар (медальләр)...-ы; *нумизматическая коллекция* — иске акчалар (медальләр) коллекциясе.

**НУ-НУ'** *разг. фам.* — 1. я-я! я ... әле! *ну-ну, вставай* — я-я, тор! я, тор әле; *ну-ну, не сердись!* — я-я, ачуланма! 2. исең китәр; *он такого натворил, что ну-ну!* — аның эшләгән эшләренә исең китәр!

**НУ'НЦИЙ** *м.* — нунций (Рим папасының чит дәүләттәге илчесе).

**НУ'ТЕ и НУ'ТЕ-КА, НУ'-ТКА** *межд. простореч.* — ягез, ягез әле.

**НУТРО'** *ср. мн.* нет — 1. эч, карын; 2. *перен.* күңел. ◇ **По нутру** *разг.* — күңелгә ошый. **В самом нутре души** — күңелемнең түрендә. **Здоровое нутро** *разг.* — саф күңел.

**НУТРЯНО'Й** — 1. эч ...-ы; *нутряное сало* — эч мае; 2. *перен. театр. арго* күңел биреп...; *нутряная игра* — күңел биреп уйнау.

**НЫ'НЕ** *нареч.* — к. ныңче.

**НЫ'НЕШНИЙ** — 1. *(теперешний)* хәзерге; 2. *(сегодняшний)* бүгенге; 3. быелгы.

**НЫ'НЧЕ** *нареч. разг.* — 1. *(сегодня)* бүген; 2. *(теперь)* хәзер, әле; 3. быел. ◇ **Не нынче — завтра** — бүген-иртәгә.

**НЫРНУ'ТЬ** *сов.* — 1. чуму; 2. *перен. разг. (исчезнуть из виду)* чуму, кереп күздән югалу; *нырнуть в толпу* — халык арасына кереп күздән югалу.

**НЫРО'К** *м.* — 1. *разг. фам.* к. нырнуть; 2. *зоол.* чүрәкәй (үрдәк).

**НЫРЯ'ТЬ** *несов.* — чуму.

**НЫ'ТИК** *м. разг. пренебр.* — һәрвакыт сукранучан, һәрвакыт зарланучан.

**НЫТЬ** *несов.* — 1. сызлау, әрнү; *рана ноет* — ярам сызлый; 2. *разг. пренебр.* ыңгырашу, сукрану, зарлану. ◇ **Сердце ноет** — эч поша, йөрәк әрни.

**НЭП** (новая экономическая политика) *м. мн.* нет — нэп (яңа экономик политика; Совет хөкүмәте тарафыннан 1921 елда кертелгән һәм капитализмнан социализмга күчү чоры өчен хас булган вакытлы экономик политика).

**НЭ'ПМАН** *м. истор. пренебр.* — нэпман (НЭП замапы сәүдәгәре).

**НЭ'ПОВСКИЙ** — нэп ...-ы; *Россия нэповская стала Россией социалистической* — НЭП Россиясе социалистик Россия булып әверелде.

**НЮА'НС** *м. книж.* — нюанс, оттенок, төсмер.

**НЮАНСИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. книж.* — аерым нюансларын (төсмерләрен) чагылдыру.

**НЮ'НИ**: **распустить (распускать) нюни** *разг. фам. пренебр.* — селәгәйләрне агызып елау.

**НЮ'НИТЬ** *несов. разг. фам. пренебр.* — сукранып елау, селәгәйләрен агызып елау.

**НЮ'НЯ** *м.* и *ж. разг. фам. пренебр.* — елак, мәми авыз.

**НЮХ** *м. мн.* нет — сизем, ис сизү сәләте, тойгы, сизгерлек. ◇ **С хорошим нюхом** *(о человеке) разг.* — зирәк, сизгер, үткен.

**НЮ'ХАЛЬЩИК** *м.* — иснәүче.

**НЮ'ХАТЕЛЬНЫЙ** — исни торган, борын ...-ы; *нюхательный табак* — борын тәмәкесе.

**НЮ'ХАТЬ** *несов.* — иснәү. ◇ **(И) не нюхал** *разг.* — исен дә белми (күрмәгән дә, белми дә). **Нюхать порох** *разг.* — дары исен иснәү (сугышта катнашу).

**НЯ'НЧИТЬ** *несов.* — бала карау.

**НЯ'НЧИТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. бала карау; 2. *ирон.* назлау, иркәләү; кайгысын чигү, кайгырту.

**НЯ'НЬКА** *ж. разг.* — 1. к. няня; 2. *пренебр.* нянька; *что я за нянька тебе!* — мин сиңа нянька түгел бит!

**НЯ'НЯ** *ж.* — 1. *(ухаживающая за детьми)* бала караучы; 2. *(в больницах)* няня; 3. *(уборщица в школе)* җыештыручы (хатын-кыз).

# О

**О I** *предлог с вин. п.* — 1. ...-га; *удариться о камень* — ташка бәрелү; *споткнуться о порог* — бусагага абыну; *сломать палку о колено* — таякны тезгә куеп сындыру; 2. *с предл. п.* турында, хакында, өчен; *лекция о Пушкине* — Пушкин турында лекция; *память о прошлом* — үткәннәр турында истәлек; *беспокоюсь о тебе* — синең өчен борчылам; синең турында борчылам; 3. ...-лы; *стол о трёх ножках* — өч аяклы өстәл; *палка о двух концах* — ике башлы таяк; *старик о седой бороде* — ак сакаллы карт. ◇ **Что ты, о двух головах, что ли?** — син нәрсә, башың икеме әллә? **Бок о бок** — янәшә торып; *мы работаем бок о бок* — без янәшә торып эшлибез. **О ту пору** *устар.* — ул вакытта. **О сю пору** *простореч.* — шушы көнгә

кадәр, хәзерге көнгә кадәр. **За столом посадила его возле себя о правую руку** *(Тург.)* — табынга ул аны үзенең уң ягына утыртты. **Палец о палец не ударил** — кыл да кыймылдатмады.

**О II** *межд.* — **1.** *книж. (употр. в риторическом обращении при существительном или личном местоимении)* эх, әй, и; *не хочу, о други, умирать* — эх, дуслар, үләсем килми минем; *о если б знала ты, как я тебя люблю!* — эх, минем сине ничек сөйгәнемне белсәң иде! **2.** *(восклицание, выражающее восхищение, удивление, сожаление и т. п.)* эй, ә; *о, это была бы райская жизнь!* — о, бу җәннәт тормышы булыр иде! **3.** *(при возражении или подтверждении служит для усиления утверждения или отрицания)* и, ә; *о, это слишком легко* — ә,бу бик җиңел.

**ОА'З** *м. редко* — к. оазис.

**ОА'ЗИС** *м.* — оазис (чүлләрдә үсемлекле, сулы урын); *Африканский оазис* — Африка оазисы.

**ОБ** *предлог с винит. и предл. п.* — к. о I.

**О'БА** *м.* и *ср.* — ике, икәве дә, икесе дә, һәр икесе; *оба глаза болят* — ике күзе дә авырта; *оба уха не слышат* — ике колагы да ишетми; *пришли оба* — икесе дә килде. ◇ **Гляди в оба** *разг.* — сак бул, алдыңа-артыңа карап йөр. **Обеими руками подписаться** *разг.* — дүрт куллап риза булу.

**ОБА'БИТЬСЯ** *сов. разг. фам. презр.* — **1.** *(о мужчине)* вак сүзле булып китү, хатыншаланып китү, характерсыз кешегә әйләнү, характерсыз булып китү; **2.** *(о женщине)* шапшаклану, әшәкеләнү, тупаслану.

**ОБА'БОК** *м. обл.* — каен гөмбәсе.

**ОБАГРИ'ТЬ** *сов. книж. поэт.* — **1.** кызарту, кызыл төскә кертү; *заря обагрила небо* — таң күкне кызыл төскә кертте; **2.** *(окровавить)* канга буяу.

**ОБАГРИ'ТЬСЯ** *сов. книж. поэт.* — **1.** кыпкызыл булу, кызару, кызыл төскә керү; *кругом росистая трава кровавой пеной обагрилась* (*Пушкин*) — тирә-яктагы чыклы үлән канлы күбектән кызарды; **2.** буялу; *обагриться кровью* — канга буялу.

**ОБАГРЯ'ТЬ** *несов. поэт.* — к. обагрить.

**ОБАГРЯ'ТЬСЯ** *несов. книж. поэт.* — **1.** к. обагриться; **2.** *страд.* кызартылу, кызыл төскә кертелү; канга буялу.

**ОБАЛДЕВА'ТЬ** *несов. простореч.* — аптырап калу, аңгыралану, миңгерәүләнү, аңлау сәләтен югалту.

**ОБАЛДЕ'ЛЫЙ** — шашкан, тилергән, миңгерәүләнгән; *вбежал, как обалделый* — шашкан кеше кебек килеп керде.

**ОБАЛДЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *простореч.* — аптырап калу, аңгыралану, миңгерәүләнү. ◇ **До обалдения** *шутл. фам.* — шаккатарлык, искитәрлек, искиткеч; *хороша до обалдения* — искиткеч шәп, искиткеч яхшы, шаккатарлык матур.

**ОБАЛДЕ'ТЬ** *сов. простореч.* — к. обалдевать.

**ОБАЛДУ'Й** *м. простореч. бран.* — аңгыра, тинтәк, миңгерәү, мәнсез, юньсез, күзле бүкән.

**ОБА'ЛТЫВАТЬ** *несов. простореч.* — к. оболтать.

**ОБАНДЕРО'ЛИВАТЬ** *несов.* — к. обандеролить.

**ОБАНДЕРО'ЛИТЬ** *сов. спец.* — бандерольләү.

**ОБАНКРО'ТИТЬСЯ** и *устар.* **ОБАНКРУ'ТИТЬСЯ** *сов.* — **1.** банкрот булу, малыннан язу, бөлү; **2.** *перен.* банкрот булу, (идея ягыннан) тулы һәлакәткә очрау; *политика соглашательства обанкротилась* — килешүчәнлек политикасы банкрот булды, банкротлыкка чыкты.

**ОБАСУРМА'НИТЬ** *сов. разг. устар. доревол.* — мөселманлаштыру, мөселман диненә кертү.

**ОБАСУРМА'НИТЬСЯ** *разг. устар. доревол.* — мөселманлашу, мөселман диненә керү, мөселман диненә күчү.

**ОБАЯ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — күңелне тарту, тәэсир, ягымлы тәэсир итү, сокландыргыч тәэсир итү; *быть под обаянием музыки* — музыка тәэсиренә бирелү.

**ОБАЯ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — сөйкемлелек, кешегә тирән тәэсир итә торган ягымлылык, сокландыргыч тәэсир итү(чәнлек), бик яхшы тәэсир итү(чәнлек).

**ОБАЯ'ТЕЛЬНЫЙ** — сокландыргыч, ягымлы; сөйкемле; *обаятельной тайной ночь июльская лежит* (*Тютчев*) — июль төне сокландыргыч сер булып җирне каплап алган; *обаятельный человек* — сөйкемле кеше, ягымлы кеше.

**ОББЕ'ГАТЬ** *сов. разг.* — к. обежать 4.

**ОББЕГА'ТЬ** *несов.* — к. оббежать.

**ОББЕЖА'ТЬ** *сов.* — **1.** йөгереп йөреп чыгу, йөгереп әйләнеп чыгу; *ребёнок оббежал все комнаты* — бала бөтен бүлмәләрне йөгереп йөреп чыкты; **2.** йөгереп узып китү; *мальчики оббежали девочек* — малайлар кыз балаларны йөгереп узып киттеләр; **3.** *(миновать во время бега)* читләтеп йөгереп үтү.

**ОББИВА'ТЬ** *несов. простореч.* — к. оббить.

**ОББИВА'ТЬСЯ** *несов.* — **1.** к. оббиться; **2.** *страд.* кагып төшерелү; сусәртеп бетерелү; **3.** тышлану.

**ОББИ'ТЬ** *сов. редко* — к. обить.

**ОББИ'ТЬСЯ** *сов. редко* — к. обиться.

**ОББРЫ'ЗГАТЬ** *сов.* — к. обрызгать.

**ОБВА'Л** *м.* — **1.** ишелү, ишелеп төшү, җимерелеп төшү (яр яки шахталарда); *здание грозит обвалом* — йорт җимерелеп төшәргә тора; *горная дорога закрыта по случаю обвала* — тау ишелеп төшү сәбәпле, тау юлы ябык; **2.** ишелеп төшкән кар өемнәре яки кыялар.

**ОБВА'ЛИВАТЬ I** *несов.* — к. обвалить.

**ОБВА'ЛИВАТЬ II** *несов.* — к. обвалять.

**ОБВА'ЛИВАТЬСЯ I** *несов.* — **1.** к. обвалиться; **2.** *страд.* ишеп төшерелү, җимереп төшерелү; **3.** ишгез салыну.

**ОБВА'ЛИВАТЬСЯ** II *несов. страд.* — әвәләнү, аунатылу.

**ОБВА'ЛИСТЫЙ** *обл.* — җимерелеп төшүчән, ишелеп төшүчән.

**ОБВАЛИ'ТЬ** *сов.* — 1. ишеп төшерү, җимереп төшерү, тәртеп аудару; *обвалить поленницу дров* — әрдәнәне ишеп төшерү; 2. нигез салу (өй әйләнәсенә); *обвалить избу землёю* — өй әйләнәсенә нигез салу (туфрак өеме белән әйләндереп алу).

**ОБВАЛИ'ТЬСЯ** *сов.* — җимерелеп төшү, коелып төшү, җимерелү, ишелү, ишелеп төшү; *дом обвалился* — өй җимерелеп төшкән; *штукатурка обвалилась* — штукатурка коелып төшкән.

**ОБВА'ЛКА** *ж. мн.* нет, *спец.* — итне сөякләреннән аеру, сөякне иттән аеру.

**ОБВАЛОВА'НИЕ** *ср. мн.* нет, *тех.* — к. обваловать.

**ОБВАЛОВА'ТЬ** *сов. тех.* — тирәли вал салып чыгу, туфрак өеме белән әйләндереп алу (су басудан саклану өчен), валлар салу, валлар белән әйләндереп алу; *обваловать берега реки* — елга буйларына валлар салып чыгу.

**ОБВАЛЯ'ТЬ** *сов.* — әвәләү; *обвалять котлету в муке* — котлетны онда әвәләү; 2. аунату; *обвалять в снегу* — карда аунату.

**ОБВА'РИВАТЬ** *несов.* — к. обварить.

**ОБВА'РИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. обвариться; 2. *страд.* пешекләнү, кайнар су белән чайкалу.

**ОБВАРИ'ТЬ** *сов. простореч.* — 1. пешекләү, кайнар су белән чайкау; *обварить овощи* — яшелчәләрне кайнар су белән чайкау; *обварить курицу* — тавыкны пешекләү; 2. пешерү; *обварить кипятком руку* — кулны кайнар суга пешерү.

**ОБВАРИ'ТЬСЯ** *сов. простореч.* — пешү; *обвариться кипятком* — кайнар суга пешү.

**ОБВЕВА'ТЬ** *несов.* — к. обвеять.

**ОБВЕВА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — җилгәрелү, суырылу.

**ОБВЕЗТИ'** *сов.* — 1. (тирәли) әйләндереп йөртеп чыгу; *обвезти вокруг города* — шәһәр тирәли әйләндереп йөртеп чыгу (атка, машинага яки башка берәр нәрсәгә утыртып); 2. *простореч. (развозя, снабдить)* йөртеп өләшеп чыгу, йөктә йөртеп өләшеп чыгу.

**ОБВЕ'ИВАТЬ** *несов.* — к. обвеять 1.

**ОБВЕНЧА'ТЬ** *сов.* — никахландыру, никах уку.

**ОБВЕНЧА'ТЬСЯ** *сов.* — никахланышу, никах укыту; *уедемте потихоньку да и обвенчаемся* — сиздермичә генә китик тә никахланышыйк.

**ОБВЕРНУ'ТЬ** *сов.* — төрү, төреп кую, урау, урап кую, тышлау; *обвернуть книгу в бумагу* — китапны кәгазь белән тышлау; *обвернуть дерево на зиму войлоком* — агачны кышка киез белән төреп кую.

**ОБВЕРТЕ'ТЬ** *сов. разг.* — 1. *(обмотать несколько раз)* урап кую, чорнап кую; 2. *(вертя, сгладить, сделать более свободным)* боргалап шомарту, боргалап бушайту (винтны); 3. *простореч. (поженить)* тиз генә өйләндерү, баш-күзле иту; *а там обвертим, да и вся недолга* — аннан тиз генә өйләндерәбез дә, эше бетте, вәссәлам. ◇ **Обвертеть вокруг пальца** *разг.* — кәкре каенга терәтү, төпсез чанага утырту; төпсез чуманга утырту.

**ОБВЕРТЕ'ТЬСЯ** *сов. простореч.* — уралу, чорналу (бернічә тапкыр).

**ОБВЁРТКА** *ж.* — 1. *только ед. (действие)* к. обвернуть; 2. *обл. (портянка)* чолгау.

**ОБВЁРТЫВАТЬ** I *несов.* — к. обвернуть.

**ОБВЁРТЫВАТЬ** II *несов.* — к. обвертеть 1.

**ОБВЕ'РЧИВАТЬ** *несов. разг.* — к. обвертеть 2.

**ОБВЕ'С** I *м. мн.* нет, *простореч.* — 1. алдап ким үлчәү; 2. үлчәгәндә ялгышу, ялгыш үлчәү.

**ОБВЕ'С** II *м. спец.* — обвес, пәрдә (махсус техник максатлар өчен берәр материалдан ясалган чаршау).

**ОБВЕ'СИТЬ** *сов. разг.* — 1. *(недовесить с целью обмана)* ким үлчәү; 2. *простореч.* элу, элеп чыгу, тагу, тагып чыгу.

**ОБВЕ'СИТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. *(ошибиться при взвешивании)* үлчәгәндә ялгышу; 2. *простореч.* к. обвешаться.

**ОБВЕСТИ'** *сов.* — 1. тирәли йөртеп чыгу, әйләндереп йөртеп чыгу (җәяү); *обвести гостей вокруг дома* — кунакларны йорт тирәли әйләндереп йөртеп чыгу; 2. киртәләп чыгу, әйләндереп алу, койма тоту, койма тотып чыгу; *обвести сад забором* — бакчаны койма белән әйләндереп алу, бакчага койма тоту; 3. түгәрәкләп сызып алу; *обвести город на карте* — картада шәһәрне түгәрәкләп сызып алу; 4. күз йөртеп чыгу, күздән кичерү; *обвести глазами комнату* — бүлмәгә күз йөртеп чыгу; 5. сызып чыгу; *обвести карандашный чертёж тушью* — карандаш белән ясалган чертёж өстеннән тушь белән йөртеп (сызып) чыгу; 6. *спорт.* уратып үтү; *он обвёл защитников и забил мяч в ворота* — ул сакчыларны уратып үтте дә тупны капкага кертте. ◇ **Обвести вокруг пальца** *разг.* — кәкре каенга терәтү, төпсез чуманга утырту.

**ОБВЕ'ТРЕТЬ** *сов.* — җил ашау, җилдән тупаслану, җилдән каралу, җил кагу.

**ОБВЕ'ТРИВАТЬ** *несов.* — к. обветрить.

**ОБВЕ'ТРИВАТЬСЯ** *несов.* — к. обветриться.

**ОБВЕ'ТРИТЬ** *сов.* — 1. җилдән ашату; *обветрить лицо* — битне җилдән ашату; 2. *безл.* җилдән ярылу; *мне обветрило губы* — минем иреннәрем (җилдән) ярылган; иреннәрем (җилгә) ярылган.

**ОБВЕ'ТРИТЬСЯ** *сов.* — җил кагу, җил ашау, җилдән каралу, җилдән тупаслану.

**ОБВЕТША'ЛОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — искергәнлек, тузганлык.

**ОБВЕТША'ЛЫЙ** *книж.* — искергән, тузган, иске; *обветшалая кровля* — искергән түбә, иске түбә; *обветшалая мода* — искергән мода.

**ОБВЕТША'ТЬ** *сов. книж.* — 1. искерү, искереп бетү, тузу, тузып бетү; 2. *устар.* кулланыштан чыгу, искерү.

**ОБВЕ'ШАТЬ** *сов.* — элеп чыгу, тагып бетерү, элеп тутыру (төрле әйберләр бетерү); *обвешать стену картинами* — стенага картиналар элеп тутыру.

**ОБВЕ'ШАТЬСЯ** *сов.* — өстенә тагу, тагып бетерү.

**ОБВЕ'ШИВАТЬ** I *несов.* — к. обвесить.

**ОБВЕ'ШИВАТЬ** II *несов.* — к. обвешать.

**ОБВЕ'ШИВАТЬ** III *несов. спец.* — к. обвешить.

**ОБВЕ'ШИВАТЬСЯ** I *несов. разг.* — 1. к. обвеситься; 2. *страд.* үлчәгәндә алдану.

**ОБВЕ'ШИВАТЬСЯ** II *несов.* — 1. к. обвешаться; 2. *страд.* элеп бетерелү, элеп тутырылу, элеп чыгылу.

**ОБВЕ'ШИВАТЬСЯ** III *несов. спец.* — маяклар утыртып чыгылу.

**ОБВЕШИ'ТЬ** *сов. спец.* — маяклар утыртып чыгу.

**ОБВЕ'ЯТЬ** *сов.* — 1. *с.-х. (очистить зерно)* җилгәреп тазарту; 2. җил исеп китү, җилләндерү (төрле яктан); *он зимой тебя согреет, летом холодом обвеет* — кыш көне ул сине җылытыр, җәен җилләндерер. ◇ **Минувшим нас обвеет** — үткәннәр искә төшеп китәр.

**ОБВИВА'ТЬ** *несов.* — к. обвить.

**ОБВИВА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. обвиться; 2. *страд.* чорналу, уралу; каплап алыну, каплану; кочаклап алыну.

**ОБВИНЕ'НИЕ** *ср.* — 1. гаепләү, гаепләнү, гаеп; *предъявить обвинение* — гаепләү; *судить по обвинению в краже* — урлауда гаепләп хөкем итү; 2. гаепләү карары; *вынести обвинение* — гаепләү карары чыгару; 3. *(обвиняющая сторона)* гаепләүче як.

**ОБВИНИ'ТЕЛЬ** *м. книж.* — гаепләүче; *государственный обвинитель* — дәүләт гаепләүчесе.

**ОБВИНИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж. право* — гаепләү...-ы; *обвинительный акт* — гаепләү акты.

**ОБВИНИ'ТЬ** *сов.* — 1. гаепләү, гаеп ташлау, гаеп тагу; *в неблагодарности он меня не обвинит* — яхшылыкның кадерен белмәүдә ул мине гаепли алмас; ул мине, яхшылыкның кадерен белми дип, гаепли алмас; 2. *офиц. право* гаепләү карары чыгару, гаепле дип табу; *суд обвинил его в краже* — суд аны урлауда гаепләп карар чыгарды.

**ОБВИНЯ'ЕМЫЙ** — гаепләнүче (судта); *обвиняемый в растрате* — растрата ясауда гаепләнүче.

**ОБВИНЯ'ТЬ** *несов.* — 1. *офиц. право (возбуждать уголовное преследование)* җавапка тарту, хөкемгә тарту; 2. *(осуждать)* гаепләү, гаеп ташлау; 3. *(выступать обвинителем)* гаепләп чыгу (судта).

**ОБВИНЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — гаепләнү; *преступник обвинялся в краже со взломом* — җинаятьче йозак ватып урлауда гаепләнгән иде.

**ОБВИСА'ТЬ** *несов.* — салынып тору.

**ОБВИ'СЛЫЙ** — салынып төшкән, сәлперәйгән; *похудевший, с обвислыми мешками кожи на щеках* — ябыккан, яңак тиреләре капчык төсле салынып төшкән.

**ОБВИ'СНУТЬ** *сов.* — салынып төшү; *поля у шляпы обвисли* — эшләпәнең читләре салынып төшкән.

**ОБВИ'ТЬ** *сов.* — 1. чорнау, чорнап алу, урау, урап алу; *она обвила косу вокруг головы* — ул чәч толымын башына ураган; 2. *перен.* каплап алу, каплау; *мгла обвила вершины гор* — тау башларын караңгылык каплаган; 3. *перен.* кочаклау, кочаклап алу, сарып алу; сарылу; *он руками обвил шею матери* — ул куллары белән анасының муенына сарылды (муеннан кочаклап алды).

**ОБВИ'ТЬСЯ** *сов. книж. поэт.* — уралу, чорналу; *лента обвилась вокруг ног* — тасма аякка уралды.

**ОБВО'Д** *м.* — 1. *(действие)* к. обвести; 2. кайма; *окно с узорными обводами* — бизәк төшерелгән каймалы тәрәзә.

**ОБВОДИ'ТЬ** *несов.* — к. обвести.

**ОБВОДИ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. әйләндереп алыну (читән, койма, киртә, канау һәм башкалар белән); 2. әйләндереп йөртеп чыгылу; 3. түгәрәкләп сызып алыну.

**ОБВОДНЕ'НИЕ** *ср.* — *(действие)* к. обводнить. ◇ **Законтурное обводнение** *спец.* — тирәли суландыру.

**ОБВОДНИ'ТЕЛЬНЫЙ** *тех.* — суландыру...-ы; суландыра торган; *обводнительные работы* — суландыру эшләре.

**ОБВОДНИ'ТЬ** *сов. тех.* — 1. суландыру, су белән тәэмин итү (каналлар, коелар, буалар ясап); *обводнить степь* — даланы суландыру; 2. суын арттыру; *обводнить пруд* — буаның суын арттыру.

**ОБВО'ДНЫЙ** — әйләнмә, тирәли әйләндереп ала торган; *обводный канал* — әйләнмә канал, тирәли әйләндереп ала торган канал.

**ОБВОДНЯ'ТЬ** *несов. тех.* — к. обводнить.

**ОБВОДНЯ'ТЬСЯ** *несов. страд. тех.* — суландырылу, су белән тәэмин ителү; суы арттырылу, суы күбәйтелү.

**ОБВО'ДЧИК** *м. спец.* — каймалаучы.

**ОБВО'З** *м. мн.* нет, *спец.* — к. обвозить.

**ОБВОЗИ'ТЬ** *несов.* — 1. тирәли әйләндереп йөртү; 2. йөртеп таратып чыгу.

**ОБВОЗИ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — тирәли әйләндереп йөртеп чыгылу; йөртеп таратып чыгылу.

**ОБВОЛА'КИВАТЬ** *несов.* — к. обволочь.

**ОБВОЛА'КИВАТЬСЯ** *несов.* — томалану, каплану, төрле яктан каплап алыну; *залитый водой огонь обволакивается дымом* — утка су сипсән, төтен белән каплана.

**ОБВОЛОСА'ТЕТЬ** *сов. простореч.* — чәч, сакал каплау; чәч, сакал басу.

**ОБВОЛО'ЧЬ** *сов.* — 1. каплап алу; *тучи обволокли небо* — болытлар күк йөзен каплап алган; 2. *мед.* каплау, сылап каплау. ◇ **Его обволокли мещанские дрязги**

и сплетни — ул мещан ыгы-зыгылары һәм гайбәтләре эченә кереп баткан.

**ОБВОЛО'ЧЬСЯ** *сов.* — к. обволакиваться.

**ОБВОРА'ЖИВАТЬ** *несов.* — к. обворожить.

**ОБВОРА'ЧИВАТЬ** *несов. просторе́ч.* — к. обворотить.

**ОБВОРА'ЧИВАТЬСЯ** *несов. страд. просторе́ч.* — төрелү, уралу, тышлану.

**ОБВОРОВА'ТЬ** *сов. разг.* — урлап бетерү, талап чыгу, урлап чыгу; *а ты спи больше, так и всего обворуют* (А. Островский) — син болай күп йокласаң, бөтен әйбереңне урлап бетерерләр әле.

**ОБВОРО'ВЫВАТЬ** *несов.* — к. обворовать.

**ОБВОРОЖИ'ТЕЛЬНЫЙ** — сокландыргыч, сөйкемле, күңелне үзенә тарта торган, гүзәл; *обворожительная улыбка* — сокландыргыч елмаю.

**ОБВОРОЖИ'ТЬ** *сов.* — сокландыру, таңга калдыру, үзенә карату, шаккатыру, искитәрү; *он обворожил всех своим талантом* — ул үзенең таланты белән бөтен кешене сокландырды.

**ОБВОРОТИ'ТЬ** *сов. просторе́ч.* — к. обвернуть.

**ОБВЫКА'ТЬ** *несов. просторе́ч.* — күнегү, күнегә бару, гадәтләнү, ияләшү, ияләшә бару.

**ОБВЫ'КНУТЬ** *сов. просторе́ч.* — күнегү, күнегеп житү, ияләшү, ияләшеп житү.

**ОБВЯЗА'ТЬ** *сов.* — 1. урап бәйләү, урап бәйләп кую; *обвязать пакет верёвкой* — пакетны бау белән урап бәйләп кую; 2. *разг. (обвешать)* элеп бетерү, күп итеп элү, күп итеп тагу; 3. *спец.* бәйләп чыгу; *обвязать платок кружевами* — яулык читенә челтәр бәйләп чыгу; 4. бәйләп бирү (оек, бияләй); *всех обшила, обвязала* — барысына да киемнәр тектем, оек-бияләйләр бәйләп бирдем.

**ОБВЯЗА'ТЬСЯ** *сов.* — 1. уратып бәйләү, төренү; *обвязаться платком* — шәлгә төренү; 2. *разг. (обвешаться)* тагып тутыру, тагып бетерү, элеп бетерү.

**ОБВЯ'ЗКА** *ж. разг.* — 1. к. обвязать; 2. *просторе́ч. (повязка)* бәйләвеч, бау; 3. *тех. (приспособление, соединяющее части какого-н. сооружения)* беркеткеч.

**ОБВЯ'ЗЫВАТЬ** *несов.* — к. обвязать.

**ОБВЯ'ЗЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. обвязаться; 2. *страд.* уратып бәйләнү.

**ОБВЯ'ЛИВАТЬ** *несов. спец.* — каклау, каклап хәзерләү, каклап кую.

**ОБВЯ'ЛИВАТЬСЯ** *несов. страд. спец.* — каклану, каклап хәзерләнү, каклап куелу.

**ОБВЯ'ЛИТЬ** *сов.* — к. обвяливать.

**ОБГА'ДИТЬ** *сов. просторе́ч. вульг.* — пычрату, пычратып бетерү, пычратып ташлау, шакшылау, шакшылап бетерү.

**ОБГА'ДИТЬСЯ** *сов. просторе́ч. вульг.* — пычранып бетү, шакшыланып бетү.

**ОБГА'ЖИВАТЬ** *несов. просторе́ч. вульг.* — к. обгадить.

**ОБГА'ЖИВАТЬСЯ** *несов. просторе́ч. вульг.* — 1. к. обгадиться; 2. *страд.* пычратылу, шакшыландырылу, пычратып бетерелү.

**ОБГИБА'ТЬ** *несов. просторе́ч.* — к. огибать.

**ОБГИБА'ТЬСЯ** *несов. просторе́ч.* — к. огибаться.

**ОБГЛА'ДИТЬ** *сов.* — 1. *(сделать гладким)* шомарту, шомартып чыгу; 2. үтүкләп бирү; *всех обстирала, обгладила* — барысының да керен юып, үтүкләп бирде.

**ОБГЛА'ДЫВАТЬ** *несов.* — тирәли кимереп чыгу.

**ОБГЛА'ЖИВАТЬ** *несов.* — к. обгладить.

**ОБГЛОДА'ТЬ** *сов.* — к. обгладывать.

**ОБГЛО'ДОК** *м. разг.* — кимерелгән кисәк, кимерелгән сөяк.

**ОБГЛО'ДЫШ** *м. просторе́ч.* — к. обглодок.

**ОБГЛЯДЕ'ТЬ** *сов. просторе́ч.* — к. оглядеть.

**ОБГЛЯДЕ'ТЬСЯ** *сов. просторе́ч.* — к. оглядеться.

**ОБГЛЯ'ДЫВАТЬ** *несов.* — к. оглядеть.

**ОБГЛЯ'ДЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. оглядеться; 2. *страд.* карап чыгылу, күз йөртеп чыгылу.

**ОБГНИВА'ТЬ** *несов. разг.* — өстән черү; читләре, кырыйлары черү.

**ОБГНИ'ТЬ** *сов. разг.* — өстән череп бетү; читләре, кырыйлары череп бетү.

**ОБГОВА'РИВАТЬ** *несов. просторе́ч.* — к. обговорить.

**ОБГОВА'РИВАТЬСЯ** *несов. страд. просторе́ч.* — алдан әйтеп куелу, фикер алышып куелу.

**ОБГОВОРИ'ТЬ** *сов. просторе́ч.* — 1. к. оговорить; 2. *(обсудить)* фикер алышып кую.

**ОБГОНЯ'ТЬ** *несов.* — узу, узып китү.

**ОБГОНЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — артта калдырылу.

**ОБГОРА'ЖИВАТЬ** *несов. просторе́ч.* — тирәли әйләндереп алу (читән, койма һәм башка белән), киртә тоту, киртәләү.

**ОБГОРА'ЖИВАТЬСЯ** *несов. просторе́ч.* — 1. к. обгородиться; 2. *страд.* әйләндереп алыну (читән, киртә, койма һ. б. белән).

**ОБГОРА'ТЬ** *несов.* — к. обгореть.

**ОБГОРЕ'ЛЫЙ** — тирәли янган, көйгән. ◇ **Обгорелое полено** — кисәү.

**ОБГОРЕ'ТЬ** *сов.* — 1. өсте яну, тирәли яну, янып күмерләнү, янып бетү; *верхний этаж обгорел* — югары кат янып күмерләнгән; 2. *разг.* пешеп бетү; *мальчик на пожаре обгорел* — малай янгында пешеп беткән; 3. янып китү; *фитиль ещё не обгорел, как следует* — филтә яхшылап янып китмәгән әле.

**ОБГОРОДИ'ТЬ** *сов. просторе́ч.* — к. огородить.

**ОБГОРОДИ'ТЬСЯ** *сов. просторе́ч.* — к. огородиться.

**ОБГРЫЗА'ТЬ** *несов.* — к. обгрызть.

**ОБГРЫЗА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — кимереп бетерелү, кимерелеп бетү.

**ОБГРЫ'ЗОК** *м. просторе́ч.* — кимерелгән әйбер, кимерек.

**ОБГРЫ'ЗТЬ** *сов.* — кимереп бетерү.

**ОБГРЫ'ЗЫВАТЬ** *несов.* — к. обгрызать.

**ОБГРЫ'ЗЫВАТЬСЯ** *несов.* — к. обгрызаться.

**ОБДАВА'ТЬ** *несов.* — к. обдать.

**ОБДАВА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. обдаться; 2. *страд.* коендырылу, коендырып алыну, чайкап алыну, су йөгертеп алыну.

**ОБДА'РИВАТЬ** *несов.* — к. обдарить.

**ОБДА'РИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — бүләкләнү.

**ОБДАРИ'ТЬ** *сов.* — бүләк өләшеп чыгу, бүләкләп чыгу, бүләк биреп чыгу.

**ОБДА'ТЬ** *сов.* — коендыру, коендырып алу, чайкап алу, су йөгертеп алу; *обдать фрукты тёплой водой* — җимешләрне җылы су белән йөгертеп алу, чайкап алу; *его обдало волной* — аны дулкын коендырды. ◇ **Меня обдало холодом** — тәнемә салкын йөгерде. **Обдать презрением кого-н.** *книжн.* — кемгә дә булса нәфрәтле караш ташлау.

**ОБДА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — коену, өскә су кою.

**ОБДЕ'ЛАТЬ** *сов.* — 1. эшкәртү; *обделать кожу* — күнне эшкәртү; 2. тезеп чыгу, җәеп чыгу; *обделать яму камнем* — чокырга таш тезеп чыгу; 3. кую, кысага утырту; *обделать драгоценный камень в золото* — асыл ташны алтын кысага утырту; 4. уңышлы башкарып чыгу; җайлау; *обделать все дела* — бөтен эшләрне уңышлы башкарып чыгу; 5. *простореч. фам.* тәпсез чуманга утырту, алдау; 6. *разг. эвф.* к. обгадить.

**ОБДЕ'ЛАТЬСЯ** *сов. разг.* — җайлану, рәтләнү; *на другой день всё обделалось, как нельзя лучше* — икенче көнне бөтен нәрсә көткәннән дә яхшырак җайланды.

**ОБДЕ'ЛИСТЫЙ** *простореч.* — житез; оста; *обделистый парень* — житез егет (үзенә кирәкле эшләрне оста башкара белүче).

**ОБДЕЛИ'ТЬ** *сов.* — 1. (өлештән) мәхрүм итү, өлешсез калдыру; *природа обделила его умом* — табигать аны акылдан мәхрүм иткән; 2. *простореч.* бүләкләү, бүләк бирү, бүләк өләшү.

**ОБДЕ'ЛКА** *ж.* — 1. *только ед. (действие)* к. обделать 1, 2, 3; 2. *(украшение, оправа)* бизәк; кыса, кыны.

**ОБДЕ'ЛОЧНЫЙ** — эшкәртү...-ы, эшкәртә торган; *деревообделочный завод* — агач эшкәртү заводы.

**ОБДЕ'ЛЫВАТЬ** *несов.* — к. обделать.

**ОБДЕ'ЛЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. обделаться; 2. *страд.* эшкәртелү; җәеп чыгылу; куелу, утыртылу.

**ОБДЕ'ЛЬЩИК** *м.*, **ОБДЕ'ЛЬЩИЦА** *ж. спец.* — эшкәртүче, бизәкләүче.

**ОБДЕЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. обделить.

**ОБДЕЛЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — мәхрүм ителү, өлешсез калдырылу.

**ОБДЁРГАННЫЙ** *разг.* — 1. йолкып бетерелгән; 2. йолкыш, сәләмә; *ты вот с дворянами водишься, а ходишь общипанная да обдёрганная* (А. Островский) — син менә дворяннар белән аралашасың, ә үзең йолкыш, сәләмә йөрисең.

**ОБДЁРГАТЬ** *сов. простореч.* — йолкып бетерү, өзеп бетерү; *обдёргать листья с куста* — куакның яфракларын өзеп бетерү; 2. йолкып тигезләп чыгу, тирә-яктан йолкып чыгу; *обдёргать воз с соломой* — салам йөген тирә-яктан йолкып тигезләп чыгу.

**ОБДЁРГИВАТЬ** *несов.* — к. обдёргать.

**ОБДЁРГИВАТЬСЯ** *несов.* — к. обдёрнуться.

**ОБДЕРЖА'ТЬСЯ** *сов. простореч.* — бер тиенсез калу, расходлану, күп расход тоту; *я обдержался* — мин күп расход тоттым.

**ОБДЕРНИ'ТЬ** *сов. спец.* — кәс җәеп чыгу, кәс белән каплап чыгу, кәс түшәп чыгу, чирәм белән каплап чыгу; *обдернить канаву* — канауны кәс белән каплап чыгу.

**ОБДЁРНУТЬ** *сов.* — к. одёрнуть I.

**ОБДЁРНУТЬСЯ** *сов.* — к. одёрнуться.

**ОБДЕРНЯ'ТЬ** *несов. спец.* — к. обдернить.

**ОБДЕРНЯ'ТЬСЯ** *несов. страд. спец.* — кәс белән каплану, кәс түшәлү.

**ОБДИРА'ЛА** *м.* — 1. талаучы, тереләй талаучы, тунаучы, взятка алучы; 2. *зоол.* күбәләкнең бер төре.

**ОБДИРА'ТЕЛЬСТВО** *ср. мн.* нет — терелэй тунау (бик кыйммәт бәя белән сату).

**ОБДИРА'ТЬ** *несов.* — к. ободрать.

**ОБДИРА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. ободраться; 2. *страд.* туналу, каезлану; йолыккалап бетерелү.

**ОБДИ'РКА** *ж. спец.* — 1. *(действие)* к. обдирать; 2. *обл.* ярдырып тарттырылган он; ярдырылган ярма; 3. *(обдирная мельница)* яргыч.

**ОБДИ'РНЫЙ** — ярдырып тарттырылган, ярдырган; *обдирная мука* — ярдырып тарттырылган он.

**ОБДУВА'ЛА** *м. простореч.* — алдакчы, ялганчы.

**ОБДУВА'ТЬ** I *несов.* — к. обдуть I.

**ОБДУВА'ТЬ** II *несов. простореч.* — к. обдуть II.

**ОБДУ'ВКА** *ж. мн.* нет, *спец.* — өрдереп тазарту, өрдереп чистарту; *обдувка котлов от сажи* — казаннарны өрдереп корымнан тазарту.

**ОБДУ'МАННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книжн.* — уйлап эшләнгәнлек; *обдуманность решения* — карарның уйлап эшләнгәнлеге.

**ОБДУ'МАННЫЙ** — һәр ягы уйланган, уйлап эшләнгән, уйлап...-ган; *обдуманный шаг* — уйлап эшләнгән адым; *обдуманный ответ* — уйлап бирелгән җавап.

**ОБДУ'МАТЬ** *сов.* — һәр ягын уйлау, төрле яктан уйлап карау.

**ОБДУ'МАТЬСЯ** *сов. разг.* — фикер туплау; *пока пил кофе, он старался обдуматься* — кофе эчкән арада ул фикерләрен тупларга тырышты.

**ОБДУ'МЫВАТЬ** *несов.* — к. обдумать.

**ОБДУ'МЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. обдуматься; 2. *страд.* һәрьяклап уйланылу.

**ОБДУ'НУТЬ** *сов. разг.* — к. обдуть I.

**ОБДУ'РИВАТЬ** *несов. простореч.* — к. обдурить.

**ОБДУРИ'ТЬ** *сов. простореч.* — алдау, тәпсез чуманга утырту.

**ОБДУ'ТЬ** I *сов.* — 1. өрдереп чистарту, җилдә тотып тазарту; 2. өреп төшерү; *достал портрет и со всех сторон обдул пыль* — портретны алдым да төрле яктан тузаннарын өреп төшердем. ◇ **Ветром тебя обдует, лучше тебе будет** — җилдә торырсың, хәлең бераз яхшырыр (А. Островский).

**ОБДУ'ТЬ** II *сов. простореч.* — 1. (*обмануть*) алдау, хәйләләп алдау, кәкре каенга терәтү; 2. *фам.* оту (уенда); *обдуть в карты* — карта уенында оту.

**ОБДУ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. (*обдуть себя, сдуть с себя*) өреп төшерү (үзеннән өстеннән); 2. (*опиться*) *просторечь.* күбенгәнче эчү, эчеп күбенү.

**О'БЕ** *ж.* — к. оба.

**ОБЕ'ГАТЬ** *сов. разг.* — йөгереп йөреп чыгу, йөгереп тирәли әйләнеп чыгу; *обегал весь город* — бөтен шәһәрне йөгереп йөреп чыктым.

**ОБЕГА'ТЬ** I *несов. разг.* — обе́гать.

**ОБЕГА'ТЬ** II *несов.* — читкә кагу, тайчану, читләтү; *вы меня не обегайте, я гожусь на многое* (А. Островский) — сез мине читкә какмагыз, мин бик күп нәрсәгә ярый торган кеше.

**ОБЕ'ГАТЬСЯ** *сов. спец.* — йөрергә өйрәнү, йөрергә күнегү; *лошадь обегалась в упряжи* — ат җигүдә йөрергә күнекте.

**ОБЕ'Д** *м.* — 1. обед, төшке аш; *рабочие ушли на обед* — эшчеләр обедка киттеләр; 2. аш мәҗлесе; *торжественный обед* — тантаналы аш мәҗлесе; 3. төш, төшке аш вакыты; *к обеду вернёмся* — төшкә кайтып җитәрбез.

**ОБЕ'ДАТЬ** *сов.* — төшке аш ашау, обед ашау.

**ОБЕ'ДЕННЫЙ** — 1. аш...-ы, көндезге аш...-ы; *обеденный стол* — аш өстәле; *обеденное время* — көндезге аш вакыты; 2. төшке, көндезге; *обеденный перерыв* — төшке перерыв, көндезге перерыв.

**ОБЕДНЕ'ЛЫЙ** *разг.* — ярлыланган, фәкыйрьлеккә төшкән.

**ОБЕДНЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — ярлылану, фәкыйрьлеккә төшү; *обеднение крестьянства дореволюционной деревни* — революциягә кадәр авыл крестьяннарының фәкыйрьлеккә төшүе.

**ОБЕДНЕ'ТЬ** *сов.* — ярлылану, фәкыйрьләнү, фәкыйрьлеккә төшү.

**ОБЕДНИ'ТЬ** *сов.* — ярлыландыру, фәкыйрьлеккә төшерү, фәкыйрьләндерү.

**ОБЕ'ДНЯ** *ж. церк.* — (христианнарда) иртәнге яки көндезге гыйбадәт. ◇ **Испортить всю обедню** — бөтен эшне бозу, бөтен эшнең кызыгын җибәрү.

**ОБЕДНЯ'ТЬ** I *несов.* — к. обеднить.

**ОБЕДНЯ'ТЬ** II *сов. обл.* — к. обеднеть.

**ОБЕ'ДЫВАТЬ** *несов. многокр. разг.* — обед ашаштыргалау.

**ОБЕЖА'ТЬ** *сов.* — 1. йөгереп тирәли әйләнеп чыгу; *обежать поляну* — аланны йөгереп тирәли әйләнеп чыгу; 2. (*пробежать мимо чего-нибудь*) йөгереп читләтеп узып китү; 3. *спорт.* (*опередить в беге*) узу, узып китү; 4. *разг.* (*бегая, побывать в разных местах*) йөгереп йөреп чыгу; 5. (*избежать, уклониться*) читкә китү, качу.

**ОБЕЗБО'ЛИВАНИЕ** *ср. мн.* нет, *мед.* — (*действие*) к. обезболивать.

**ОБЕЗБО'ЛИВАТЬ** *несов. мед.* — авыртуын сизмәслек хәлгә китерү, авыртуын бетерү.

**ОБЕЗБО'ЛИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — авыртуы бетерелү, авыртуы сизмәслек хәлгә китерелү.

**ОБЕЗБО'ЛИТЬ** *сов.* — к. обезболивать.

**ОБЕЗВО'ДЕТЬ** *сов.* — сусызлану, сусыз калу.

**ОБЕЗВО'ДИТЬ** *сов.* — сусызландыру, дымсызландыру; *обезводить бумажную массу* — кәгазь массасын дымсызландыру.

**ОБЕЗВО'ЖИВАТЬ** *несов.* — к. обезводить.

**ОБЕЗВО'ЛЕТЬ** *сов.* — ихтыярсызлану, ихтыярсыз булып калу, җебеп калу.

**ОБЕЗВО'ЛИВАТЬ** *несов. книж.* — к. обезволить.

**ОБЕЗВО'ЛИТЬ** *сов. книж.* — ихтыярсызландыру, мөстәкыйльлеген бетерү, ихтыярсыз итү.

**ОБЕЗВРЕ'ДИТЬ** *сов.* — зыянсызландыру, зарарсызландыру; зарар тидермәслек итү.

**ОБЕЗВРЕ'ЖИВАТЬ** *несов.* — к. обезвредить.

**ОБЕЗВРЕ'ЖИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — зыянсызландырылу, зарарсызландырылу; зыян, зарар тидермәслек ителү.

**ОБЕЗГЛА'ВЕТЬ** *сов. книж.* — башсыз калу.

**ОБЕЗГЛА'ВИТЬ** *сов. книж.* — 1. башсыз калдыру, башын кисеп ташлау; 2. *перен.* (*лишить руководства*) җитәкчесез калдыру, башлыксыз калдыру.

**ОБЕЗГЛА'ВЛИВАТЬ** *несов. книж.* — к. обезглавить.

**ОБЕЗГЛА'ВЛИВАТЬСЯ** *несов. страд. книж.* — 1. башы кисеп ташлану; 2. җитәкчесез калдырылу, башлыксыз калдырылу.

**ОБЕЗГОЛО'СЕТЬ** *сов. разг.* — тавышсыз калу (җырчы турында).

**ОБЕЗДЕ'НЕЖЕТЬ** *сов. разг.* — акчасыз калу, акча бетү.

**ОБЕЗДЕ'НЕЖИТЬ** *сов. разг.* — акчасыз калдыру.

**ОБЕЗДО'ЛЕННЫЙ** — бәхетсезлеккә төшерелгән, өлештән мәхрүм ителгән; изелгән, җәберләнгән; *обездоленные массы пролетариев капиталистических стран* — капиталистик илләрнең җәберләнгән пролетариат массалары.

**ОБЕЗДО'ЛИВАТЬ** *несов.* — к. обездолить.

**ОБЕЗДО'ЛИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — бәхетсезлеккә төшерелү, мәхрүм ителү.

**ОБЕЗДО'ЛИТЬ** *сов.* — бәхетсезлеккә төшерү, өлештән мәхрүм итү, җәберләү, изү.

**ОБЕЗДУ'ШИВАТЬ** *несов. книж.* — к. обездушить.

**ОБЕЗДУ'ШИТЬ** *сов. книж.* — әшәкеләндерү, бозу, рухи интереслардан мәхрүм итү.

**ОБЕЗЖИ'РИВАНИЕ** *ср. мн.* нет, *спец.*— к. обезжиривать.

**ОБЕЗЖИ'РИВАТЬ** *несов. спец.* — к. обезжирить.

**ОБЕЗЖИ'РИВАТЬСЯ** *несов. страд. спец.* — мае бетерелү, майсызландырылу.

**ОБЕЗЖИ'РИТЬ** *сов. спец.* — майсызландыру; маен бетерү; *обезжирить шерсть мыльной водой* — йонны сабынлы су белән юып майсызландыру.

**ОБЕЗЗАРА'ЖИВАТЬ** *несов.* — йогышсызландыру, дезинфекция ясау.

**ОБЕЗЗАРА'ЖИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — йогышсызландырылу, дезинфекция ясалу.

**ОБЕЗЗАРА'ЗИТЬ** *сов.* — к. обеззараживать.

**ОБЕЗЗЕМЕ'ЛИВАТЬ** *несов. книж.* — к. обезземелить.

**ОБЕЗЗЕМЕ'ЛИВАТЬСЯ** *несов. страд. книж.* — жирсез калдырылу; җирдән мәхрүм ителү.

**ОБЕЗЗЕМЕ'ЛИТЬ** *сов. книж.* — җирсез калдыру, җирдән мәхрүм итү.

**ОБЕЗЗУ'БЕТЬ** *сов. разг.* — тешләре төшеп бетү, тешсез калу, тешсезләнү.

**ОБЕЗЛЕ'СЕНИЕ** *ср. мн.* нет, *спец.* — 1. к. обезлесеть; 2. к. обезлесить.

**ОБЕЗЛЕ'СЕТЬ** *сов. книж. спец.* — урмансыз калу, урман бетү; *район обезлесел* — районда урманнар беткән.

**ОБЕЗЛЕ'СИТЬ** *сов. книж. спец.* — урмансыз калдыру, урманнарны кисеп бетерү.

**ОБЕЗЛЕ'СИТЬСЯ** *сов. книж. спец.* — урмансыз калу, урманнар бетү.

**ОБЕЗЛИ'ЧЕННЫЙ** — 1. *книж.* шәхси үзлекләрен (үзенчәлекләрен) югалткан; *обезличенный человек* — шәхси үзлекләрен югалткан кеше; 2. җавапсыз калдырылган, һичкемнең җаваплылыгына тапшырылмаган, беркемгә дә беркетелмәгән; *обезличенные станки* — һичкемнең җаваплылыгына тапшырылмаган станоклар; *обезличенная работа* — аерым җавап бирүчесе булмаган эш; 3. *экон. фин.* иясез (кемнең кулында булса, шуныкы санала торган); *обезличенные облигации* — иясез облигацияләр.

**ОБЕЗЛИ'ЧИВАТЬ** *несов.* — к. обезличить.

**ОБЕЗЛИ'ЧИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. обезличиться; 2. *страд.* шәхси үзлекләре (үзенчәлекләре) бетерелү; 3. ялгыз җаваплылыкка бирелмәү, җавапчысыз калдырылу.

**ОБЕЗЛИ'ЧИТЬ** *сов.* — 1. шәхси үзлекләрен бетерү; 2. аерым кешегә беркетмәү; җавапчысыз калдыру; *обезличить работу* — эшне аерым кешегә беркетмәү.

**ОБЕЗЛИ'ЧИТЬСЯ** *сов.* — 1. шәхси үзенчәлекләре бетү; 2. аерым кешегә беркетелмәү.

**ОБЕЗЛИ'ЧКА** *ж. мн.* нет — обезличка, индивидуаль җавапсызлык, иясезлек; ялгыз җаваплылык булмау, беркемнең дә җаваплы булмавы; 2. *перен.* шәхси үзенчәлекләре бетерелү; *обезличка в показе героев повести* — повестьның геройларын күрсәткәндә шәхси үзенчәлекләрен бетерү.

**ОБЕЗЛОША'ДЕТЬ** *сов. обл. с.-х.* — атсыз калу.

**ОБЕЗЛОША'ДИТЬ** *сов. обл.* — атсыз калдыру.

**ОБЕЗЛЮ'ДЕТЬ** *сов.* — кешесез калу.

**ОБЕЗЛЮ'ДИТЬ** *сов.* — кешесез калдыру.

**ОБЕЗМА'ТОЧЕТЬ** *сов. спец.* — анасыз калу (бал кортлары турында).

**ОБЕЗНАДЁЖИВАТЬ** *несов. устар.* — өметсезләндерү, өметен өзү.

**ОБЕЗНАДЁЖИТЬ** *сов.* — к. обезнадёживать.

**ОБЕЗНО'ЖЕТЬ** *сов.* — аяктан язу, аяксыз калу; *конь обезножел* — ат аяксыз калды.

**ОБЕЗНО'ЖИТЬ** *сов. разг.* — аяксыз калдыру, аяктан яздыру; *обезножила меня ходьба* — йөрү мине аяксыз калдырды.

**ОБЕЗОБРА'ЖИВАТЬ** *несов.* — к. обезобразить.

**ОБЕЗОБРА'ЖИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. обезобразиться; 2. *страд.* ямьсезләндерелү, гарипләндерелү, шыксызландырылу.

**ОБЕЗОБРА'ЗИТЬ** *сов.* — кыяфәтсезләндерү, ямьсезләндерү, гарипләндерү, шыксызландыру; *война обезобразила их лица* — сугыш аларның йөзләрен ямьсезләндергән.

**ОБЕЗОБРА'ЗИТЬСЯ** *сов.* — кыяфәтсезләнү, ямьсезләнү, гарипләнү, шыксызлану.

**ОБЕЗОПА'СИТЬ** *сов.* — куркынычтан, хәвеф-хәтәрдән саклау; *обезопасить границы от вторжения врага* — чикләрне дошман басып керү куркынычыннан саклау.

**ОБЕЗОПА'СИТЬСЯ** *сов.* — куркынычтан, хәвеф-хәтәрдән саклану.

**ОБЕЗОРУ'ЖИВАТЬ** *несов.* — к. обезоружить.

**ОБЕЗОРУ'ЖИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — коралсызландырылу.

**ОБЕЗОРУ'ЖИТЬ** *сов.* — 1. *(отнять оружие)* коралсызландыру, коралын алу; 2. *перен.* каршы чыга алмаслык итү; *веский довод обезоружил оппонента* — төпле дәлил оппонентны каршы чыга алмаслык итте; 3. *(смирить, укротить, успокоить)* басынкыландыру, тыйнакландыру, тынычландыру.

**ОБЕЗУ'МЕТЬ** *сов.*—акылдан язу, акылдан шашу.

**ОБЕЗУ'МИТЬ** *сов.* — акылдан яздыру, акылдан шаштыру.

**ОБЕЗЬЯ'НА** *ж.* — 1. маймыл; 2. *перен. (очень некрасивый человек)* маймыл, ямьсез кеше, кыяфәтсез кеше; 3. *(тот, кто кривляется)* кыланчык (кеше), маймыл.

**ОБЕЗЬЯ'НИЙ** — маймыл...-ы; *обезьяний мех* — маймыл мехы.

**ОБЕЗЬЯ'НИТЬ** *несов. разг. пренебр.* — маймыллану, кешегә ияреп кылану.

**ОБЕЗЬЯ'НКА** *ж. разг.* — кечкенә маймыл.

**ОБЕЗЬЯ'ННИК** *м.* — 1. маймыл читлеге (зоопаркта); 2. *разг. устар.* к. обезьянщик.

**ОБЕЗЬЯ'ННИЧАТЬ** *несов. разг. пренебр. редко* — к. обезьянить.

**ОБЕЗЬЯ'ННИЧЕСТВО** *ср. мн.* нет, *разг. пренебр. редко* — маймыллык.

**ОБЕЗЬЯНОПОДО'БНЫЙ** — маймылга охшаган, маймылсыман.

**ОБЕЗЬЯ'НСТВО** *ср. мн.* нет, *разг. пренебр.* — к. обезьянничество.

**ОБЕЗЬЯ'НЩИК** *м. разг. устар.* — маймыл уйнатучы, маймыл биетүче.

**ОБЕЛИ'СК** *м.* — обелиск (өскә таба очлаеп менә торган күп кырлы янсә түгәрәк багана формасындагы таш һәйкәл).

**ОБЕЛИ'ТЬ** *сов.* — 1. *обл.* (*побелить*) агарту, агартып чыгу, акшарлап чыгу; *обелить стены* — стеналарны агарту; 2. *перен.* (*оправдать*) аклау, гаепсез дип табу; 3. *истор.* (*освободить от податей, повинностей*) түләүләрдән, салымнардан азат итү.

**ОБЕЛИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. *обл.* агару; 2. *перен.* аклану, гаепсез дип табылу; 3. *истор.* түләүләрдән, салымнардан азат ителү.

**ОБЕ'ЛКА** *ж. мн.* нет, *обл.* — агарту, акшарлау.

**ОБЕ'ЛЬНЫЙ** *истор.* — түләүләрдән, салымнардан азат ителгән; *обельные крестьяне* — түләүләрдән, салымнардан азат ителгән крестьяннар.

**ОБЕЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. обелить 2, 3.

**ОБЕЛЯ'ТЬСЯ** *несов.* — к. обелиться 2, 3.

**О'БЕРЕГ** *м. обл.* — 1. (*охрана*) сакчы; 2. (*талисман*) бөти, тылсым; 3. (*заклинание*) им-том, өшкерү.

**ОБЕРЕГА'ТЬ** *несов.* — к. оберечь.

**ОБЕРЕГА'ТЬСЯ** *несов.* — к. обеaccording.

**ОБЕРЕ'ЧЬ** *сов.* — саклау, саклап калу; *оберечь леса от порубки* — урманнарны кисүдән саклап калу.

**ОБЕРЕ'ЧЬСЯ** *сов.* — саклану, сак булу, сакланып калу.

**ОБЕРНУ'ТЬ** *сов.* — 1. төрү, тышлау; *обернуть книжку бумагой* — китапны кәгазьгә төрү; 2. урау, урап кую; *обернуть косу вокруг головы* — чәч толымын баш әйләнәсенә урау; 3. *разг.* бору; *обернуть дело в свою пользу* — эшне үз җаена бору; 4. *простореч.* әйләндерү; *обернуть брюки* — чалбарны тискәре ягына әйләндерү; 4. әвереллдерү; *колдунья обернула его лисой* — сихерче аны төлкегә әверелдерде; 5. оборотка җибәрү; *купец разбогател, трижды обернув свой капитал* — купец капиталын өч тапкыр оборотка җибәреп баеган; 6. эшләп бетерү, башкарып чыгу; *обернул в два дня все свои дела и уехал домой* — ике көндә бөтен эшләрен башкарып бетерде дә өенә кайтып китте; 7. барып кайту; *до города ехать далеко, в один день не обернём* — шәһәргә барырга ерак, бер көндә барып кайта алмабыз. ◇ **Обернуть вокруг пальца** *разг.* — кәкре каенга терәтү.

**ОБЕРНУ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. борылу, әйләнү, читкә (артка) әйләнеп карау; *не гляди на неё, обернись ты к ней задом* — карама син аңа, артың белән борыл; 2. *перен. разг.* бүтән юл алу, үзгәрү; *нам остаётся только выжидать, как обернутся события* — безгә вакыйгаларның нинди төс алуын көтеп торырга гына кала; 3. оборот ясау; *капитал обернулся в год* — капитал бер елда оборот ясады; 4. *разг.* эшне бетерү, эшләп ташлау; *в два дня обернулся* — ике көндә эшен бетерде; 5. әйләнеп кайту, әйләнеп йөреп кайту; *в две недели обернёшься* — ике атнада әйләнеп кайтырсың; 6. кыен хәлдән уңышлы рәвештә арыну, эшләп чыгу, очлап чыгу; *а ведь с двумястами рублями, пожалуй, не обернёшься* — ике йөз сум белән генә бәлкем очлап чыга алмассындыр; 7. *разг.* (*в сказках и поверьях*) әверелү; *бес обернулся в пса* — җен эткә әверелде; 8. *простореч.* төрену; *обернуться в одеяло* — юрганга төрену.

**О'БЕР-ПРОКУРО'Р** *м. офиц. дорезол.* — обер-прокурор (1. сенат департаментының башлыгы; 2. синод башында торучы, синод башлыгы).

**ОБЁРТКА** *ж.* — 1. *только ед. простореч.* төрү; 2. тышлык; 3. *бот.* чәчәк төргече.

**ОБЕРТО'Н** *м. физ. муз.* — обертон, өстәмә тембр (тавышка яңа төсмер, яңа сыйфат бирә торган өстәмә тон).

**ОБЁРТОЧНЫЙ** — төрү...-ы, әйбер төрә торган; *обёрточная бумага* — әйбер төрә торган кәгазь.

**ОБЁРТЫВАТЬ** *несов.* — к. обернуть 1, 3, 7.

**ОБЁРТЫВАТЬСЯ** *несов.* — к. обернуться 1, 2, 4, 5, 6, 7, 8.

**ОБЕСКРО'ВИТЬ** *сов. книж.* — 1. кансыз калдыру, канын агызып бетерү; 2. *перен.* көчсезләндерү, хәлсезләндерү, тормышка сәләтен бетерү, таркаулык кертү, җитәкчесез калдыру (оешманы); *капиталисты стремятся обескровить рабочий класс* — капиталистлар эшчеләр сыйныфын көчсезләндерергә тырышалар. ◇ **Переводчик обескровил оригинал** — тәрҗемәче оригиналны җансызландырган.

**ОБЕСКРО'ВЛИВАТЬ** *несов. книж.* — к. обескровить.

**ОБЕСКРО'ВЛИВАТЬСЯ** *несов. страд. книж.* — 1. кансызландырылу; 2. *перен.* көчсезләндерелү, хәлсезләндерелү, тормышка сәләте бетерелү, таркауландырылу.

**ОБЕСКРЫ'ЛИВАТЬ** *несов. книж.* — к. обескрылить.

**ОБЕСКРЫ'ЛИТЬ** *сов.* — 1. канатларын өзү, өзеп ташлау; *обескрылить муху* — чебеннең канатларын өзү; 2. *перен.* (*лишить вдохновенности*) илһамсызландыру, канатын сындыру.

**ОБЕСКУРА'ЖИВАТЬ** *несов.* — к. обескуражить.

**ОБЕСКУРА'ЖИТЬ** *сов.* — өметен өзү, ышанычын бетерү, аптырашта калдыру.

**ОБЕСПА'МЯТЕТЬ** *сов.* — 1. хәтерсезләнү, хәтер югалу; *в последние годы он совсем обеспамятел* — соңгы елларны аның хәтере бөтенләй югалды; 2. һуш китү, аңны югалту, һуштан язу; *я ударился головой и обеспамятел* — мин башымны бәреп һуштан яздым.

**ОБЕСПЕ'ЧЕНИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — 1. тәэмин итү; тәэминат; *материальное*

*обеспечение в старости* — картлыкта материаль яктан тәэмин итү; 2. гарантия; *вы без всякого обеспечения взяли из банка 19 тысяч* — сез бернинди гарантиясез банктан 19 мең сум акча алгансыз.

**ОБЕСПЕ'ЧЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. тәэмин ителгән булу, тәэмин ителү; 2. муллык, житешлек.

**ОБЕСПЕ'ЧИВАТЬ** *несов.* — к. обеспечить.

**ОБЕСПЕ'ЧИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. к. обеспечиться; 2. *страд.* тәэмин ителү.

**ОБЕСПЕЧИ'ТЕЛЬНЫЙ** *офиц. право* — тәэмин итү...-ы; *обеспечительный договор* — тәэмин итү договоры.

**ОБЕСПЕ'ЧИТЬ** *сов.* — 1. тәэмин итү, тәэмин итеп кую, кирәк-ярагын житештереп кую; *обеспечить свою семью* — семьяңны тәэмин итү, семьяңның кирәк-яракларын житештереп кую; 2. тәэмин итү, гарантияләү; *обеспечить мир во всём мире* — бөтен дөньяда тынычлыкны тәэмин итү; *обеспечить победу* — җиңүне тәэмин итү; *обеспечить высокий урожай* — югары уңышны тәэмин итү; 3. *устар.* саклап калу, чараларын күрү; *обеспечить население от эпидемий* — халыкны йогышлы авырулардан саклап калу чараларын күрү.

**ОБЕСПЕ'ЧИТЬСЯ** *сов.* — хәзерләп кую, тәэмин итеп кую; *обеспечиться необходимым* — барлык кирәк-яракларны хәзерләп кую, үзеңне барлык кирәк-яраклар белән тәэмин итеп кую.

**ОБЕСПЛО'ДЕТЬ** *сов.* — бала тудыру сәләтен югалту, җимеш бирү сәләтен югалту, уңыш бирү сәләтен югалту; ...-мый башлау; *корова состарилась, обесплодела* — сыер картайды, бозауламый башлады.

**ОБЕСПЛО'ДИТЬ** *сов.* — 1. бала тудырмаслык (колынламаслык, бозауламаслык) хәлгә китерү; *обесплодить лошадь* — атны колынламаслык хәлгә китерү; 2. уңыш бирмәслек хәлгә китерү; *обесплодить поля* — басуларны уңыш бирмәслек хәлгә китерү; 3. *перен. книж.* иҗат көчен бетерү; мәгънәсезләндерү; *обесплодить мысль* — фикернең иҗат көчен бетерү; фикерне мәгънәсезләндерү.

**ОБЕСПЛО'ЖИВАТЬ** *несов.* — к. обесплодить.

**ОБЕСПЛО'ЖИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. бала тудырмаслык (колынламаслык, бозауламаслык) хәлгә китерелү; җимеш, уңыш бирмәслек хәлгә китерелү; 2. *перен.* иҗат көче бетерелү.

**ОБЕСПОКО'ЕННЫЙ** — тынычсызландырылган, борчылган.

**ОБЕСПОКО'ИТЬ** *сов.* — тынычсызландыру, борчу, мазасызлау, тынгысызлау.

**ОБЕСПОКО'ИТЬСЯ** *сов.* — тынычсызлану, борчылу; *мы недоумевали, отчего так вдруг обеспокоились соседи нашим отъездом* — без киткәнгә күршеләрнең болай кинәт борчылуы безгә бик сәер тоелды.

**ОБЕССИ'ЛЕТЬ** *сов. разг.* — хәлсезләнү, көчсезләнү, көч бетү.

**ОБЕССИ'ЛИВАТЬ** *несов.* — к. обессилить.

**ОБЕССИ'ЛИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — хәлсезләндерелү, көчсезләндерелү, көче бетерелү.

**ОБЕССИ'ЛИТЬ** *сов.* — хәлсезләндерү, көчсезләндерү, көчен бетерү.

**ОБЕССЛА'ВИТЬ** *сов.* — яман атка калдыру, яман атын сату, яман атын чыгару, хурлыкка төшерү.

**ОБЕССМЕ'РТИТЬ** *сов. книж.* — мәңгеләштерү, мәңге онытылмаслык итү; *поэзия Пушкина обессмертила его имя* — Пушкинның поэзиясе аның исемен мәңгеләштерде.

**ОБЕССМЕ'РТИТЬСЯ** *сов. книж.* — мәңгеләшү (исем, яхшы ат, дан һ. б. турында).

**ОБЕССМЫ'СЛИВАТЬ** *несов.* — мәгънәсезләндерү, мәгънәсен бетерү.

**ОБЕССМЫ'СЛИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. к. обессмыслиться; 2. *страд.* мәгънәсезләндерелү.

**ОБЕССМЫ'СЛИТЬ** *сов.* — к. обессмысливать.

**ОБЕССМЫ'СЛИТЬСЯ** *сов.* — мәгънәсезләнү, мәгънәсе югалу.

**ОБЕССУ'ДИТЬ** *сов. устар.* — гаеп итү, гаепкә алу; *не обессудь* — гаеп итмә; *не обессудьте, если не сумею* — кулымнан килмәсә, гаеп итмәгез.

**ОБЕСЦВЕ'ТИТЬ** *сов.* — 1. төссезләндерү, төсен китәрү, буявын бетерү; 2. *перен.* үзенчәлекләрен бетерү; *обесцветить стиль* — стильнең үзенчәлекләрен бетерү.

**ОБЕСЦВЕ'ТИТЬСЯ** *сов.* — 1. төссезләнү, төсе бетү, буявы бетү; 2. *перен. (лишиться индивидуальных черт)* төссезләнү, үзенчәлекләре бетү, үзенчәлекләрен югалту, характерлылыгы бетү.

**ОБЕСЦВЕ'ЧИВАТЬ** *несов.* — к. обесцветить.

**ОБЕСЦВЕ'ЧИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. обесцветиться; 2. *страд.* үзенчәлекләре бетерелү.

**ОБЕСЦЕ'НИВАТЬ** *несов.* — бәясен төшерү, кыйммәтен төшерү, кадерсезләндерү.

**ОБЕСЦЕ'НИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. обесцениться; 2. *страд.* бәясе төшерелү; кадерсезләндерелү.

**ОБЕСЦЕ'НИТЬ** *сов.* — к. обесценивать.

**ОБЕСЦЕ'НИТЬСЯ** *сов.* — бәясезләнү, бәясе төшү, кадерсезләнү.

**ОБЕСЧЕ'СТИТЬ** *сов.* — хур итү, хурлыкка төшерү, абруен төшерү, йөзгә кара ягу.

**ОБЕ'Т** *м. книж.* — 1. *(обязательство из религиозных побуждений)* нәзер; 2. *(зарок, обещание)* вәгъдә, сүз.

**ОБЕТОВА'НИЕ** *ср. книж. торж. устар.* — тантаналы вәгъдә.

**ОБЕТОВА'ННЫЙ** *книж.*: обетованная земля — 1. вәгъдә ителгән җир (библия легендасы буенча яһүдиләргә вәгъдә ителгән җир); 2. *перен.* берәүнең барырга ашкынып тора торган җире.

**ОБЕЧА'ЙКА** *ж.*, **ОБЕ'ЧКА** *ж. обл.* — торпыча, кыса (мәсәлән, иләк кысасы, барабан кысасы).

**ОБЕЩА'НИЕ** *ср.* — вәгъдә, сүз; *давать обещание* — вәгъдә бирү, сүз бирү.

**ОБЕЩА'ТЬ** *сов.* и *несов.* — 1. вәгъдә

бирү, сүз бирү; *обещал, так держи слово* — сүз биргәнсең икән, сүзеңдә тор; 2. өмет бирү, өмет булу; *урожай обещал быть хорошим* — уңышның яхшы булачагына өмет бар иде.

**ОБЕЩА'ТЬСЯ** *сов.* и *несов.* — вәгъдә бирү, сүз бирү.

**О'БЖА'** *ж.* — 1. *(оглобля у сохи)* сука тәртәсе; 2. *(рукоятка у сохи или плуга)* сука яки сабан тоткасы; 3. *истор. (единица пахотной земли)* сөрү җирен үлчәү берәмлеге.

**ОБЖА'ЛОВАНИЕ** *ср. офиц. право* — к. обжаловать.

**ОБЖА'ЛОВАТЬ** *сов. офиц. право* — жалоба бирү (түбәнге орган карарына риза булмыйча югары органга рәсми жалоба бирү).

**ОБЖА'РИВАТЬ** *несов.* — к. обжарить.

**ОБЖА'РИВАТЬСЯ** *несов.* — к. обжариться.

**ОБЖА'РИТЬ** *сов.* — куыру, кыздыру (һәр яктан).

**ОБЖА'РИТЬСЯ** *сов.* — куырылу, кыздырылу (һәр яктан).

**ОБЖА'ТЬ** I *сов.* — кысу, сыгу; *обжать бельё* — керне сыгу.

**ОБЖА'ТЬ** II *сов. обл.* — урып бетерү; *обжать рожь* — арышны урып бетерү.

**ОБЖА'ТЬСЯ** I *сов. разг.* — сыгылу; *бельё хорошо обжалось* — кер яхшы сыгылган.

**ОБЖА'ТЬСЯ** II *сов.* — урак уру эшләрен бетерү; *мы уж обжались и обкосились* — без урак уру һәм печән чабу эшләрен бетердек инде.

**ОБЖЕВА'ТЬ** *сов. простореч.* — чәйнәп бетерү.

**ОБЖЁВЫВАТЬ** *несов. простореч.* — к. обжевать.

**ОБЖЕ'ЧЬ** *сов.* — 1. яндыру; *обжечь конец бревна* — бүрәнәнең башын яндыру; 2. пешерү; *я сегодня обожгла утюгом левую руку* — мин бүген сул кулымны үтүкка пешердем; 3. яндыру, чыныктыру; *обжечь кирпич* — кирпеч яндыру; 4. утка тоту; *обжечь свечу* — шәмне утка тоту.

**ОБЖЕ'ЧЬСЯ** *сов.* — 1. пешү; *обжечься горячим чаем* — кайнар чәйгә пешү; 2. *перен.* кабу, яну, авыз пешү, оттыру (зур уңышсызлыкка очрау); *обжёгся он на этом деле* — бу эштә аның авызы пеште. ◇ **Обжёгшись на молоке, будешь дуть и на воду** — авызы пешкән өреп капкан.

**ОБЖИВА'ТЬ** *несов. разг.* — торырлык хәлгә китерү.

**ОБЖИВА'ТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. к. обжиться; 2. *страд.* торырлык хәлгә китерелү.

**ОБЖИ'Г** *м. тех.* — 1. яндыру; *обжиг кирпичей* — кирпеч яндыру; 2. яндырып эшкәртеләсе (чыныктырыласы) әйберләр күләме.

**ОБЖИГА'ЛА** *м. спец.* — яндыручы; *бригада обжигал кирпичного завода* — кирпеч заводының кирпеч яндыручылар бригадасы.

**ОБЖИГА'ЛЬНЫЙ** *тех.* — яндырып чыныктыру...-ы; *обжигальная печь* — яндырып чыныктыру миче.

**ОБЖИГА'ЛЬЩИК** *м. тех.* — к. обжигала.

**ОБЖИГА'ТЬ** *несов.* — к. обжечь.

**ОБЖИГА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. обжечься; 2. *страд.* яндырылу, яндырып чыныктырылу.

**ОБЖИ'М** *м. мн.* нет, *тех.* — кысу.

**ОБЖИМА'ТЬ** *несов.* — к. обжать.

**ОБЖИМА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. обжаться; 2. *страд.* кысылу, сыгылу.

**ОБЖИ'МКА** *ж. только ед. тех.* — к. обжим.

**ОБЖИ'МОК** *м.* — 1. *разг.* кысып йомарланган кисәк; 2. *(выжатые остатки)* сыгынты, түп; 3. *только мн. спец. (волокна, остающиеся от мятья льна)* сүс.

**ОБЖИ'Н** *м. мн.* нет, *обл.* — к. обжать II.

**ОБЖИНА'ТЬ** *несов. обл.* — к. обжать II.

**ОБЖИНА'ТЬСЯ** *несов. обл.* — 1. к. обжаться; 2. *страд.* урып бетерелү.

**ОБЖИ'НКА** *ж. обл.* — 1. *только ед.* кысу; 2. *только мн.* уңыш бәйрәме (руларда урак уру беткәч була торган бәйрәм).

**ОБЖИ'НОК** *м. обл.* — урылмый калган башаклар.

**ОБЖИРА'ЛА** *м. простореч. вульг.* — 1. кеше җилкәсен кимерүче; 2. бирән корсак, гуҗ.

**ОБЖИРА'ТЬ** *несов. простореч.* — кеше җилкәсен кимерү.

**ОБЖИРА'ТЬСЯ** *несов. простореч. вульг.* — тыгыну, үтләгәнче ашау.

**ОБЖИТО'Й** — торырга яраклаштырылган, торырлык хәлгә китерелгән.

**ОБЖИ'ТЬ** *сов. разг.* — торырлык хәлгә китерү.

**ОБЖИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. күнегү, өйрәнү, ияләшү (яңа өйгә, яңа урынга); *ласточка обжилась под крышей* — карлыгач өй түбәсе астына ияләште; 2. *устар.* кору, булдыру; *обжиться семьёй* — семья кору.

**ОБЖО'Г** *м. разг.* — к. ожог.

**ОБЖО'РА** *м.* и *ж. разг. неодобр.* — комагай, бирән корсак, туймас тамак.

**ОБЖО'РКА** *ж. устар.* — обжорка (арзан бәягә күп итеп ашарга мөмкин булган ашханә).

**ОБЖО'РЛИВОСТЬ** *ж. мн.* нет, *разг.* — комагайлык, туймас тамаклык, бирән корсаклык.

**ОБЖО'РЛИВЫЙ** *разг.* — туймас, туймас тамак, бирән.

**ОБЖО'РНЫЙ** *разг. устар.*: обжорный ряд — базарда пешкән ашлар белән сату итә торган урын.

**ОБЖО'РСТВО** *ср. мн.* нет — туймас тамаклык, комагайлык.

**ОБЖУ'ЛИВАТЬ** *несов. простореч.* — утырту, алдау, алдап алу.

**ОБЖУ'ЛИТЬ** *сов. простореч.* — к. обжуливать.

**ОБЗАВЕДЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — 1. к. обзавести, обзавестись; 2. җиһаз; йорт кирәк-яраклары; *полное обзаведение* — барлык йорт кирәк-яраклары.

**ОБЗАВЕСТИ'** *сов.* — алу, кирәк-яраклар алып бирү. ◇ **Обзавести их хозяйством** — аларга йорт торгызып бирү.

**ОБЗАВЕСТИ'СЬ** *сов.*— кирәк-яраклар алу, кирәк-яракны булдыру, җиһазлану, кору, корып җибәрү; *пришла пора обзавестись своим домом* — үзеңә йорт корырга вакыт җитте.

**ОБЗАВОДИ'ТЬ** *несов.*— к. обзавести.

**ОБЗАВОДИ'ТЬСЯ** *несов. разг.*— к. обзавестись.

**ОБЗАКО'НИВАТЬ** *несов. простореч. обл.*— законлаштыру.

**ОБЗАКО'НИВАТЬСЯ** *несов. простореч. обл.*— 1. к. обзакониться; 2. *страд.* законлаштырылу.

**ОБЗАКО'НИТЬ** *сов. простореч. обл.*— к. обзаконивать.

**ОБЗАКО'НИТЬСЯ** *сов. простореч. обл.*— законлашу.

**ОБЗВА'НИВАТЬ** *несов. фам.*— к. обзвонить.

**ОБЗВОНИ'ТЬ** *сов. разг.*— шалтыратып чыгу (телефоннан); *обзвонить всех знакомых* — бөтен танышларга шалтыратып чыгу.

**ОБЗИРА'ТЬ** *несов. устар.*— күздән үткәрү, карап чыгу, тикшереп чыгу.

**ОБЗНАКО'МИТЬСЯ** *сов. простореч.*— танышу, танышып чыгу, танышып бетү.

**ОБЗО'Р** *м.*— 1. *только ед. (действие)* к. обозреть; 2. күрү мөмкинлеге; *наблюдатель должен иметь хороший обзор* — күзәтүче өчен күрү мөмкинлеге яхшы булырга тиеш; 3. күзәтү, обзор (мәкалә яки докладта берәр мәсьәлә турында төрле чыганаклардан алынган мәгълүматларны кыскача җыйнап бирү); *обзор военных действий* — хәрби хәрәкәтләр барышын күзәтү.

**ОБЗО'РНЫЙ** — күзәтү...-ы, күзәтеп чыгу ...-ы; *статья носила обзорный характер* — мәкалә күзәтү характерында язылган иде.

**ОБЗЫВА'ТЬ** *несов. разг.*— к. обозвать.

**ОБИВА'ТЬ** *несов.*— к. обить. ◇ **Обивать пороги** — бусага таптау (берәр эш артыннан йөреп йөдәп бетү).

**ОБИВА'ТЬСЯ** *несов.*— к. обиться.

**ОБИ'ВКА** *ж. спец.*— 1. *(действие)* к. обить; 2. *(то, чем обивают)* тышлык, тыш; *обивка дивана* — диван тышлыгы.

**ОБИВНО'Й** — тышлык..., тышлау...-ы; *обивной материал* — тышлык материал.

**ОБИ'ДА** *ж.*— 1. үпкә, хәтер калу, күңел кырылу, хәтер калдыру; *мелкие обиды* — вак-төяккә хәтер калулар; 2. *обл. (убыток)* зыян. ◇ **Они не дадут меня в обиду** — алар мине якларлар, алар мине кыерсытырмаслар. **Не в обиду будь сказано** — хәтерегез калмасын.

**ОБИ'ДЕТЬ** *сов.*— 1. үпкәләтү, рәнҗетү, кыерсыту, хәтер калдыру, кысу; 2. *перен.* өлештән мәхрүм итү, өлешсез калдыру; *умишком-то его очень бог обидел* — ходай аны акылдан мәхрүм иткән. ◇ **Мухи не обидит** — юаш, басынкы.

**ОБИ'ДЕТЬСЯ** *сов.*— үпкәләү, хәтер калу, рәнҗү.

**ОБИ'ДНЫЙ** — хәтер калдырырлык, үпкәләтерлек, рәнҗетерлек; *обидное слово* — үпкәләтерлек сүз. ◇ **Мне обидно видеть это** — бу хәлне күрү миңа бик аяныч.

**ОБИ'ДЧИВОСТЬ** *ж. мн.* нет — үпкәләүчәнлек, хәтер калучанлык.

**ОБИ'ДЧИВЫЙ** — хәтере калучан, үпкәләүчән, гарьләнүчән, гарьчел.

**ОБИ'ДЧИК** *м.*, **ОБИ'ДЧИЦА** *ж. разг.*— үпкәләтүче, хәтер калдыручы, рәнҗетүче; *наказать обидчика* — рәнҗетүчегә җәза бирү.

**ОБИЖА'ТЬ** *несов.*— к. обидеть.

**ОБИЖА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. обидеться; 2. *страд.* кыерсытылу, өлешеннән мәхрүм ителү, өлешсез калдырылу, рәнҗетелү.

**ОБИ'ЛИЕ** *ср.*— муллык, күплек, байлык; *жить в обилии* — муллыкта яшәү.

**ОБИ'ЛОВАТЬ** *несов. книж. устар.*— к. изобиловать.

**ОБИ'ЛЬНЫЙ** — мул, бик күп, бай; *край, обильный лесом* — урманга бай як. ◇ **Обильный дождь** — коеп яуган яңгыр.

**ОБИНУ'ЯСЬ**: **не обинуясь** — уйлап тормыйча, бер дә икеләнмичә, шикләнмичә, ык-мык итмичә; *мужики, не обинуясь, подтвердили показания Трифона* — мужиклар, бер дә ык-мык итмичә, Трифонның сүзләрен расладылар.

**ОБИНЯ'К** *м. разг. устар.*: **говорить обиняками** — читләтеп сөйләү, кинаяләп сөйләү; *я буду говорить прямо, без обиняков* — мин турыдан-туры, һичбер кинаясез сөйләрмен.

**ОБИРА'ЛА** *м. простореч. неодобр.*— талаучы, тереләй талаучы, тереләй тунаучы.

**ОБИРА'ЛОВКА** *ж. простореч. ирон.*— кеше талый торган урын.

**ОБИРА'ТЬ** *несов. разг.*— к. обобрать.

**ОБИРА'ТЬСЯ** *несов. страд. разг.*— талану.

**ОБИТА'ЕМОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— кешеләр яшәү (кешеләрнең нинди дә булса бер урында яки территориядә яшәве), яшәүче халыкның тыгызлыгы.

**ОБИТА'ЕМЫЙ** — кешеләр яши торган, кешеләр тора торган; *обитаемый дом* — кешеләр яши торган йорт.

**ОБИТА'ЛИЩЕ** *ср. книж. устар. шутл.*— торак.

**ОБИТА'ТЕЛЬ** *м.*, **ОБИТА'ТЕЛЬНИЦА** *ж. книж.*— торучы, яшәүче; *обитатели Горюхина большею частью роста среднего* — Горюхинда яшәүчеләрнең күбесе урта буйлы.

**ОБИТА'ТЬ** *несов. книж.*— тору, яшәү.

**ОБИ'ТЕЛЬ** *ж. книж.*— 1. монастырь; 2. *ритор.* тору урыны, яшәү урыны.

**ОБИ'ТЬ** *сов.*— 1. *обл.* бәреп төшерү, коеп төшерү; *обить яблоки с яблони* — алмагачтан алмаларны коеп төшерү; 2. сүсәртеп бетерү; *обить рукава* — җиңнәрне сүсәртеп бетерү; 3. *разг.* бәреп бетерү; *обить руки* — кулларны бәреп бетерү; 4. тышлау; *обить диван кожей* — диванны күн белән тышлау.

**ОБИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. сүсәреп бетү; *подол платья обился* — күлмәкнең итәге сүсәреп беткән; 2. кителеп бетү; *кремни обились* — чакма ташлары кителеп беткәннәр; 3. кубып төшү; *штукатурка обилась* — штукатурка кубып төшкән.

**ОБИХО'Д** *м. мн.* нет — 1. гадәт, җай;

*посещение соседей соседями вошло в ежедневный обиход* — күршеләрнең берберсенә йөрешүе көндәлек галәт булып киткән; *жизнь шла обычным обиходом* — тормыш үзенең гадәттәге жае белән бара иде; 2. кирәк-ярак, җиһаз; *предметы домашнего обихода* — йорт кирәк-яраклары.

**ОБИХО'ДНЫЙ** — гадәткә кереп киткән, көндәлек, галәт булып киткән; көн дә кулланыла торган; *обиходные предметы* — көн дә кулланыла торган әйберләр.

**ОБКА'ЛИВАТЬ** *несов.* — к. обкалить.

**ОБКА'ЛИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — чыныктырылу.

**ОБКАЛИ'ТЬ** *сов.* — чыныктыру, утта кыздыру (төрле ягыннан).

**ОБКА'ЛЫВАТЬ** *несов.* — к. обколоть.

**ОБКА'ЛЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. *разг.* к. обколоться; 2. *страд.* китеп төшерелү.

**ОБКА'ПАТЬ** *сов.* — тамызып буяп бетерү, пычратып бетерү; *обкапать стеарином скатерть* — ашъяулыкны шәм тамызып буяп бетерү; *обкапать стол чернилами* — өстәлгә кара тамызып бетерү.

**ОБКА'ПАТЬСЯ** *сов. разг.* — өскә тамчы тамызып бетерү, тамызып буялып бетү.

**ОБКА'ПЫВАТЬ** I *несов.* — к. обкапать.

**ОБКА'ПЫВАТЬ** II *несов. разг.* — к. обкопать.

**ОБКА'ПЫВАТЬСЯ** I *несов. разг.* — к. обкапаться.

**ОБКА'ПЫВАТЬСЯ** II *несов. разг.* — тирәли казып чыгылу.

**ОБКА'РМЛИВАТЬ** *несов.* — к. обкормить.

**ОБКА'РМЛИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — үтләгәнче ашатылу, чиктән тыш күп ашатылу.

**ОБКАТА'ТЬ** *сов.* — 1. *разг.* әвәләү; *обкатать котлету в муке* — котлетны онда әвәләү; 2. *спец.* каток белән тигезләү; *обкатать дорогу* — юлны каток белән тигезләү; 3. *разг.* шуып шомарту; *обкатать ледяную гору* — боз тавын шуып шомарту; 4. йөртеп сынап карау; *обкатать новые вагоны* — яна вагоннарны йөртеп сынап карау; 5. *простореч. фам.* йөреп чыгу; *обкатал весь город* — бөтен шәһәрне йөреп чыктым (мәсәлән, атка утырып).

**ОБКАТА'ТЬСЯ** *сов.* — 1. каток белән тигезләнү; 2. йөртеп сыналу.

**ОБКАТИ'ТЬ** I *сов.* — 1. тирәли тәгәрәтеп чыгу; *обкатить обруч вокруг двора* — коршауны йорт тирәли тәгәрәтеп чыгу; 2. *простореч.* йөреп чыгу; *все районы обкатил* — бөтен районнарны йөреп чыктым.

**ОБКАТИ'ТЬ** II *сов. разг.* — к. окатить.

**ОБКАТИ'ТЬСЯ** I *сов.* — тәгәрәп (тирәли) әйләнеп чыгу; *шар обкатился вокруг стола* — шар тәгәрәп өстәл тирәли әйләнеп чыкты.

**ОБКАТИ'ТЬСЯ** II *сов. разг.* — к. окатиться.

**ОБКА'ТЫВАТЬ** I *несов.* — к. обкатать.

**ОБКА'ТЫВАТЬ** II *несов.* — к. обкатить.

**ОБКА'ТЫВАТЬСЯ** I *несов.* — 1. к. обкататься; 2. *страд.* әвәләнү; шомартылу; сынап каралу.

**ОБКА'ТЫВАТЬСЯ** II *несов.* — к. обкатиться.

**ОБКА'ЧИВАТЬ** *несов. разг.* — к. обкатить II.

**ОБКА'ЧИВАТЬСЯ** *несов.* — к. обкатиться.

**ОБКА'ШИВАТЬ** *несов.* — тирәли чабу (чалгы белән).

**ОБКА'ШИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. *обл.* к. обкоситься; 2. тирәли чабылу (чалгы белән).

**ОБКИДА'ТЬ** *сов. разг.* — ыргытып күмеп кую; *обкидать камнями* — таш ыргытып күмеп кую. ◇ Лицо обкидало сыпью — бите чабырып чыккан.

**ОБКИ'ДЫВАТЬ** *несов. разг.* — к. обкидать, обкинуть.

**ОБКИ'НУТЬ** *сов.* — 1. *простореч.* к. окинуть; 2. *разг. спорт.* ераграк ыргыту.

**ОБКЛА'ДКА** *ж.* — 1. *только ед. к.* обложить 1, 4; 2. (*то, чем обложено*) түшәлмә, түшәүгә китә торган әйбер.

**ОБКЛА'ДЧИК** *м. охот.* — обкладчик (ауда җәнлекне уратып алучы).

**ОБКЛА'ДЫВАТЬ** *несов.* — к. обложить.

**ОБКЛА'ДЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. обложиться; 2. *страд.* уратып алыну; салым салыну.

**ОБКЛА'СТЬ** *сов. простореч.* — к. обкладывать.

**ОБКЛЕВА'ТЬ** *сов.* — тирәли чукып чыгу, чукып бетерү; *цыплёнок обклевал смородину* — чебеш карлыганны чукып бетергән.

**ОБКЛЁВЫВАТЬ** *несов.* — к. обклевать.

**ОБКЛЁВЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — тирәли чукып чыгылу, чукып бетерелү.

**ОБКЛЕ'ИВАТЬ** *несов.* — к. оклеивать.

**ОБКЛЕИ'ТЬ** *сов.* — к. оклеить.

**ОБКОЛО'ТЬ** *сов.* — 1. китеп төшерү; ватып төшерү, ватып чыгу (тирә-ягыннан); *обколоть лёд с бочки* — мичкәдән бозны китеп төшерү; 2. чәнчеп бетерү; *все пальцы обколола* — бармакларымны чәнчеп бетердем.

**ОБКОЛО'ТЬСЯ** *сов. разг.* — кадалып бетү.

**ОБКО'М** *м. (областной комитет)* — ОБКОМ (өлкә комитеты).

**ОБКОПА'ТЬ** *сов. разг.* — тирәли казып чыгу.

**ОБКО'РМ** *м. мн.* нет, *спец.* — артык ашату, кирәгеннән тыш ашату, үтләгәнче ашату.

**ОБКОРМИ'ТЬ** *сов.* — артык ашату, үтләгәнче ашату, күбенгәнче ашату.

**ОБКОРНА'ТЬ** *сов. простореч.* — 1. бик кыска калдырып кисү (ат койрыгын, терлек колагын, кием итәген); 2. кыска кисеп бозу (киемне һ. б.).

**ОБКОСИ'ТЬ** *сов.* — 1. *(скосить вокруг чего-н.)* тирәли чабып чыгу (чалгы белән); 2. *обл.* (*выкосить*) чабып бетерү; 3. *обл.* (*обкосить косу*) чабып чыныктыру (чалгыны); 4. *(опередить в косьбе)* печән чапканда узып китү.

**ОБКОСИ'ТЬСЯ** *сов. обл.* — 1. *(окончить*

*покос)* печән чабу эшләрен бетерү; 2. *(о косе)* күп чабудан яхшыру.

**ОБКРА'ДЫВАТЬ** *несов.* — урлап бетерү.

**ОБКРА'СИТЬ** *сов. простореч.* — к. окрасить.

**ОБКРА'СИТЬСЯ** *сов. простореч.* — к. окраситься 2.

**ОБКРА'ШИВАТЬ** I *несов. простореч.* — к. обкрасить.

**ОБКРА'ШИВАТЬ** II *несов. простореч.* — к. обкрошить.

**ОБКРА'ШИВАТЬСЯ** I *несов. простореч.* — 1. к. обкраситься; 2. *страд.* буяп чыгылу.

**ОБКРА'ШИВАТЬСЯ** II *несов. простореч.* — к. обкрошиться.

**ОБКРОМСА'ТЬ** *сов. разг.* — аннан-моннан кискәләп бозып бетерү; *обкромсать волосы* — аннан-моннан кискәләп, чәчне бозып бетерү.

**ОБКРОШИ'ТЬ** *сов. разг.* — ваклап бетерү.

**ОБКРОШИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — кителеп бетү, ваклanып бетү, ваклану; *зуб обкрошился* — теш кителеп бетте.

**ОБКРУТИ'ТЬ** *сов. простореч.* — к. окрутить.

**ОБКРУТИ'ТЬСЯ** *сов. простореч.* — к. окрутиться.

**ОБКРУ'ЧИВАТЬ** *несов. простореч.* — к. обкрутить.

**ОБКРУ'ЧИВАТЬСЯ** *несов. простореч.* — 1. к. обкрутиться; 2. *страд.* урап куелу, чорнап куелу.

**ОБКУРГУ'ЗИТЬ** *сов. простореч.* — к. окургузить.

**ОБКУРГУ'ЗИТЬСЯ** *сов. простореч.* — к. окургузиться.

**ОБКУ'РИВАТЬ** *несов.* — к. обкурить.

**ОБКУ'РИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. обкуриться; 2. *страд.* тәмәке төтене белән төтәтелү.

**ОБКУРИ'ТЬ** *сов.* — 1. *(обдать дымом)* төтен җибәрү, төтәсләү, теслəү (дезинфекцияләү максаты белән); 2. *разг.* тәмәке төтене белән төтәтеп бетерү; 3. тарта-тарта яхшырту; *обкурить трубку* — трубканы тарта-тарта яхшырту; 4. *фам.* *(ввести кого-н. в убыток, куря на его счёт)* кешe тәмәкесен тартып бетерү.

**ОБКУРИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. к. окуриться; 2. тарта-тарта яхшыртылу (тәмәке тарту приборлары турында).

**ОБКУСА'ТЬ** *сов.* — тешләп бетерү, кимереп бетерү, чәйнәп бетерү; *обкусать ногти* — тырнакларны чәйнәп бетерү.

**ОБКУ'СЫВАТЬ** *несов.* — к. обкусать.

**ОБКУ'ТАТЬ** *сов. разг.* — к. окутать 1.

**ОБКУ'ТАТЬСЯ** *сов. разг.* — к. окутаться 1.

**ОБКУ'ТЫВАТЬ** *несов. разг.* — к. обкутать.

**ОБКУ'ТЫВАТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. к. обкутаться; 2. *страд.* төрелү, уралу, чорналу.

**ОБКУ'ШАТЬ** *сов. простореч. шутл.* — кеше азыгын ашап бетерү.

**ОБКУ'ШАТЬСЯ** *сов. простореч. ирон.* — чиктән тыш күп ашау, үтләгәнче ашау.

**ОБКУ'ШИВАТЬ** *несов. простореч.* — к. обкушать.

**ОБЛА'ВА** *ж.* — 1. аулау, камап алу (аучыларның җәнлек булган урынны камап алуы); 2. облава, камап алу (мәсәлән, качкыннарны).

**ОБЛА'ВЛИВАТЬ** *несов. спец.* — к. обловить.

**ОБЛА'ВЩИК** *м. охот. спец.* — облава ясаучы, камап алуда катнашучы.

**ОБЛАГА'ТЬ** *несов. книж. офиц.* — (салым, налог, штраф) салу.

**ОБЛАГА'ТЬСЯ** *несов. страд. книж. офиц.* — салым салыну.

**ОБЛАГОДЕ'ТЕЛЬСТВОВАТЬ** *сов. книж. устар. теперь ирон.* — яхшылык эшләү, яхшылык итү; яклау.

**ОБЛАГОЗВУ'ЧИТЬ** *сов. книж. устар.* — аһәңлеләндерү, тавышын матурландыру.

**ОБЛАГООБРА'ЖИВАТЬ** *несов. книж.* — к. облагообразить.

**ОБЛАГООБРА'ЖИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. облагообразиться; 2. *страд.* яхшыртылу, яхшы төскә, яхшы кыяфәткә кертелү.

**ОБЛАГООБРА'ЗИТЬ** *сов. книж.* — яхшы төскә кертү, яхшы кыяфәткә кертү, яхшы кыяфәт бирү.

**ОБЛАГООБРА'ЗИТЬСЯ** *сов. книж.* — яхшы төскә керү, яхшы кыяфәткә керү, яхшы кыяфәт алу.

**ОБЛАГОРА'ЖИВАТЬ** *несов. книж.* — к. облагородить.

**ОБЛАГОРА'ЖИВАТЬСЯ** *несов. книж.* — 1. к. облагородиться; 2. *страд.* токымы яхшыртылу, сыйфаты яхшыртылу.

**ОБЛАГОРО'ДИТЬ** *сов.* — 1. югары күтәрү (идея һәм әхлак ягыннан); 2. нәфисләндерү; 3. *(улучшить породу)* токымын яхшырту.

**ОБЛАГОРО'ДИТЬСЯ** *сов.* — 1. югары күтәрелү (идея һәм әхлак ягыннан); 2. нәфисләнү; 3. токымы яхшыру.

**ОБЛАДА'НИЕ** *ср. мн.* нет — биләү, хуҗа булу, кулда тоту.

**ОБЛАДА'ТЕЛЬ** *м. книж. ритор.* — биләүче, хуҗа, кулда тотучы.

**ОБЛАДА'ТЬ** *несов.* — 1. биләү, биләп тору; 2. ...-лы булу, ... -га ия булу; *обладать хорошими знаниями* — яхшы белемле булу; 3. *устар.* *(быть в половой связи)* җенси бәйләнештә булу. ◇ **Обладать собою** *устар.* — үзеңне кулда тоту. **Обладать хорошим слухом** — музыкага сәләтле булу.

**ОБЛА'ДИТЬ** *сов. обл. простореч.* — рәтләү, рәткә кертү, рәткә салу, җайлау; *обладить сани* — чананы рәтләү; *обладить дело* — эшне җайлау.

**ОБЛА'ДИТЬСЯ** *сов. простореч.* — рәтләнү; *авось, дело обладится* — ихтимал, эш рәтләнер.

**ОБЛА'ЖИВАТЬ** *несов.* — к. обладить.

**ОБЛА'ЖИВАТЬСЯ** *несов.* — к. обладиться.

**ОБЛА'ЗАТЬ** *сов. простореч.* — к. облазить.

**ОБЛА'ЗИТЬ** *сов. разг.* — (үрмәләп) йөреп чыгу, йөреп чыгу (бөтен җирне); *облазили весь лес* — бөтен урманны йөреп чыктык.

**ОБЛА'ИВАТЬ** *несов.* — к. облаять.

**О'БЛАКО** *ср.* — болыт. ◇ **Поднялось облако пыли** — тузан болыты күтәрелде. **Облако пара** — болыт кебек булып күтәрелгән пар. **Свалиться с облаков** — күктән төшкәндәй булу, көтмәгәндә килеп чыгу. **Возносить до облаков** — күккә күтәрү. **Витать в облаках, в облаках быть или в облака уноситься** *перен.* — хыял дингезендә йөзү, хыялга чуму (көндәлек реаль тормыштан ерак булу). **По лицу пробежало облако** — аның йөзендә борчылу сизелеп китте, йөзе караңгыланып китте. **Под облаками** — бик югарыда, болытлар астында.

**ОБЛА'МЫВАТЬ** *несов.* — к. обломать, обломить.

**ОБЛА'МЫВАТЬСЯ** *несов.* — к. обломаться.

**ОБЛА'ПИТЬ** *сов.* — **1.** кочаклап алу (хайваннарда); *медведь облапил охотника* — аю аучыны кочаклап алды; **2.** *простореч.* (*грубо обнять*) тупас итеп кочаклау.

**ОБЛАПО'ШИВАТЬ** *несов. простореч.* — к. облапошить.

**ОБЛАПО'ШИТЬ** *сов. простореч.* — утырту, хәйләләп алдау, кәкре каенга терәтү.

**ОБЛАСКА'ТЬ** *сов.* — күңелен күрү, якты чырай күрсәтү.

**ОБЛА'СКИВАТЬ** *несов.* — к. обласкать.

**ОБЛАСТНИ'К** *м.* — 1. *книж.* өлкәчелек тарафдары; 2. өлкә учреждениеләрендә эшләүче работник.

**ОБЛАСТНИ'ЧЕСКИЙ** — өлкәчелек...-ы; *областнические тенденции* — өлкәчелек тенденцияләре.

**ОБЛАСТНИ'ЧЕСТВО** *ср. мн.* нет, *книж.* — өлкәчелек (революциягә кадәр Россиядә өлкәләрнең экономик яктан аерым яшәве яклы булган буржуаз-либераль агым).

**ОБЛАСТНО'Й** — 1. өлкә...-ы; *областной центр* — өлкә үзәге; 2. җирле; *областное произношение* — җирле әйтелеш.

**О'БЛАСТЬ** *ж.* — 1. өлкә; *на севере целые области покрыты лесами* — төньякта бөтен бер өлкәләр урман белән капланган; 2. тирә; *ранение в области сердца* — йөрәк тирәсендәге яра; 3. (*определённая сфера деятельности*) тармак, өлкә.

**ОБЛА'ТКА** *ж.* — облатка (1. тәмсез даруләр йотар өчен бодай крахмалыннан ясалган капсуль; 2. *устар.* электә хатлар ябыштыру өчен кулланылган җилемле кәгазь).

**ОБЛАТА'ТЬ** *сов. обл.* — ямаулар салып чыгу, ямау салып бетерү.

**ОБЛАЧА'ТЬ** *несов.* — 1. *церк.* гыйбадәт киеме киендерү (попка чиркәүдә); 2. кием кидерү.

**ОБЛАЧА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. облачиться; 2. *страд.* гыйбадәт киеме кидерелү; кием кидерелү.

**ОБЛАЧЕ'НИЕ** *ср.* — 1. (*действие*) к. облачить; 2. *церк.* (*одежда служителей культа*) гыйбадәт киеме; 3. *книж. торж. ритор.* кием.

**ОБЛАЧИ'ТЬ** *сов.* — к. облачать.

**ОБЛАЧИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. гыйбадәт киеме кию; 2. *устар. книж. ритор. торж. шутл.* кием кию; *облачился я в пальтишко новенькое* — мин өр-яңа пальто кидем.

**О'БЛАЧКО** *ср.* — 1. кечкенә болыт; 2. *перен.* күңелгә ошамаган бернәрсә яки хәл. ◇ **Нет ни одного облачка** — бер генә болыт әсәре дә юк.

**О'БЛАЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *спец.* — болытлар, болыт; *самолёт вышел из сплошной облачности* — самолёт тоташ болытлар арасыннан чыкты; *переменная облачность* — алмашынучан болыт.

**О'БЛАЧНЫЙ** — болытлы, болыт каплаган; *облачное небо* — болыт каплаган күк йөзе.

**ОБЛА'ЯТЬ** *сов.* — 1. өрә-өрә ташлану (эт турында); 2. *простореч. вульг.* (*грубо выбранить*) әшәке сүзләр әйтеп сүгү.

**ОБЛЕВА'ТЬ** *сов. простореч. вульг.* — косып пычрату, косып пычратып бетерү.

**ОБЛЕВА'ТЬСЯ** *сов. простореч. вульг.* — косып пычрану, косып пычранып бетү.

**ОБЛЕГА'ТЬ** *несов.* — 1. ятып тору, сыланып тору; *платье облегало тело* — күлмәк тәнгә ятып тора иде; 2. к. облечь II.

**ОБЛЕГЧА'ТЬ** *несов.* — к. облегчить.

**ОБЛЕГЧА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. облегчиться; 2. *страд.* җиңеләйтелү, гадиләштерелү; 3. *спорт. воен.* (*в верховой езде*) җиңеләю, күтәрелеп-күтәрелеп китү; *облегчаться под левую ногу* — ат сул аягын басканда күтәрелеп-күтәрелеп китү, атның сул аягына җиңеләю.

**ОБЛЕГЧЕ'НИЕ** *ср.* — 1. к. облегчить; 2. җиңеллек; *почувствовать облегчение* — җиңеллек сизү.

**ОБЛЕГЧИ'ТЕЛЬНЫЙ** — җиңеләйтә торган, җиңеләйтү...-ы; *облегчительные приёмы* — җиңеләйтү алымнары.

**ОБЛЕГЧИ'ТЬ** *сов.* — 1. җиңеләйтү; *облегчить груз* — йөкне җиңеләйтү; 2. гадиләштерү; *облегчить конструкцию машины* — машинаның конструкциясен гадиләштерү; 3. җиңеләйтү, тынычландыру; *лекарство облегчило боль* — дару авыртуны җиңеләйтте.

**ОБЛЕГЧИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. җиңеләеп китү, җиңеләю; *работа облегчилась* — эш җиңеләйде; 2. *простореч. эвф.* (*освободить желудок испражнением, рвотой*) җиңеләю, бушану.

**ОБЛЕДЕНЕ'ЛЫЙ** — бозланган, боз каткан.

**ОБЛЕДЕНЕ'ТЬ** *сов.* — бозлану, боз белән каплану, бозга кату.

**ОБЛЁЖА'ТЬ** *сов. разг.* — озак ятып уңайландыру, ятуга җайлау, ятып иpләү; *облежать диван* — диванны озак ятып уңайландыру.

**ОБЛЁЖА'ТЬСЯ** *сов.* — ята-ята ялкауланып бетү; *он облежался и вставать не хочет* — ул ята-ята ялкауланып беткән, торасы да килми.

**ОБЛЁЖИВАТЬ** *несов. разг.* — к. облежать.

**ОБЛЁЖИВАТЬСЯ** *несов.* — к. облежаться.

**ОБЛЕЗА'ТЬ** I *несов. разг.* — к. облезть I.

**ОБЛЕЗА'ТЬ** II *несов.* — к. облезть II.

**ОБЛЕ'ЗЛЫЙ** — 1. йеган, йоны коелган, чәче коелган; 2. *перен.* (*потёртый, полинявший*) бик искергән, уңган, кыршылып беткән, тузып беткән.

**ОБЛЕ'ЗТЬ** I *сов. разг.* — 1. ню, коелу, кырылу, коелып бетү (йон, чәч турында); *волосы облезли* — чәче коелып беткән; 2. кубу, кубып бетү, кубып төшү; *краска облезла* — буявы кубып беткән.

**ОБЛЕ'ЗТЬ** II *сов.* — үрмәләп читләтеп үтү.

**ОБЛЕКА'ТЬ** *несов. книж.* — к. облечь I.

**ОБЛЕКА'ТЬСЯ** *несов. книж.* — 1. к. облечься; 2. *страд.* киертелү; чолгап алыну, каплап алыну.

**ОБЛЕ'НИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — к. облениться.

**ОБЛЕНИ'ТЬ** *сов. разг.* — ялкауландырып бетерү, ялкаулыкка өйрәтү.

**ОБЛЕНИ'ТЬСЯ** *сов.* — ялкауланып бетү.

**ОБЛЕПИ'ТЬ** *сов.* — 1. ябышу, ябышып бетү, сылану; *грязь облепила колёса* — тәгәрмәчләргә пычрак ябышкан; тәгәрмәчләргә пычрак сыланган; 2. ябыштырып, сылап чыгу; *облепить забор объявлениями* — коймага белдерүләр ябыштырып чыгу; 3. сырып алу; *меня облепила целая туча комаров* — мине озынборыннар болыт кебек сырып алды, болыттай булып сырып алды.

**ОБЛЕПИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — ябыштырып бетерү; *облепиться пластырем* — пластырь ябыштырып бетерү.

**ОБЛЕПИ'ХА** *ж. мн.* нет, *бот.* — сырганак.

**ОБЛЕ'ПЛИВАТЬ** *несов. разг.* — к. облепить.

**ОБЛЕПЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. облепить.

**ОБЛЕПЛЯ'ТЬСЯ** *несов.* — к. облепиться.

**ОБЛЕСИ'ТЬ** *сов. спец.* — урман утырту, агач утырту, урман утыртып чыгу.

**ОБЛЕСТИ'ТЬ** *сов. простореч.* — к. обольстить.

**ОБЛЕТА'ТЬ** I *несов.* — к. облететь.

**ОБЛЕТА'ТЬ** II *сов.* — 1. очып йөреп чыгу, очып әйләнеп чыгу; *лётчик облетал всю Европу* — лётчик бөтен Европаны очып әйләнеп чыккан; 2. *перен.* бик тиз арада йөреп чыгу; *она облетала всех знакомых* — ул бөтен танышларын бик тиз арада йөреп чыкты; 3. (очып) сынап карау; *пилот облетал самолёт* — пилот (очып) самолётны сынап карады.

**ОБЛЕТА'ТЬСЯ** *несов.* — очу өчен яраклы хәлгә килү, очарга җайлану, очуга ияләшеп житү; *самолёт облетался* — самолёт очарга җайланды.

**ОБЛЕТЕ'ТЬ** *сов.* — 1. очып әйләнеп чыгу; *облететь Москву на самолёте* — самолётта очып Москваны әйләнеп чыгу; 2. (*летя, перегнать*) очып узу, очып узып китү; 3. *перен.* бик тиз таралу; *весть облетела весь город* — хәбәр бөтен шәһәргә бик тиз таралды; 4. коелу, коелып бетү; *листья облетели* — яфраклар коелып беткән.

**ОБЛЁТЫВАТЬ** *несов.* — к. облетать II.

**ОБЛЁТЫВАТЬСЯ** *несов.* — к. облетаться.

**ОБЛЕ'ЧЬ** I *сов. книж.* — 1. *ритор. торж. шутл. ирон.* (*одеть*) киндерү, кигезү; 2. *перен.* әйтеп бирү; *облечь свою мысль в понятные слова* — үз фикереңне аңлаешлы сүзләр белән әйтеп бирү; 3. *перен.* бирү; *облечь доверием* — ышаныч бирү; *облечь властью* — власть бирү. ◇ **Облечь тайной** — сер итү. **Облечь славой** — данга күмү.

**ОБЛЕ'ЧЬ** II *сов.* — 1. ятып тору, сыланып тору; *платье плотно облегло фигуру* — күлмәк тәнгә ятып тора; 2. чолгап, каплап алу; *тучи облегли небо* — болытлар күк йөзен каплап алды; 3. *устар.* камап алу; *войска облегли весь город* — гаскәрләр бөтен шәһәрне камап алдылар.

**ОБЛЕ'ЧЬСЯ** *сов.* — 1. (*одеться*) киенү; 2. *устар. ритор.* гәүдәләнү; чолгап алыну.

**ОБЛИВА'НИЕ** *ср. спец.* — коену, өскә су сибү; *лечиться обливаниями* — коену белән дәвалану.

**ОБЛИВА'ТЬ** *несов.* — к. облить.

**ОБЛИВА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. облиться; 2. *страд.* коелу, түгелү, сибелү; бату, буялу (тиргә, канга). ◇ **Обливаться слезами** — күз яше түгү. **Сердце кровью обливается** — йөрәгемә кан савыла.

**ОБЛИ'ВКА** *ж. спец.* — 1. *только ед.* к. облить; 2. (*глазурь на глиняной, фаянсовой посуде*) глазурь, ялтыравык.

**ОБЛИВНО'Й** *спец.* — глазурь сибелгән, ялтыравыклы, глазурь йөгертелгән; *обливной горшок* — глазурь йөгертелгән чүлмәк.

**ОБЛИ'ВЩИК** *м. спец.* — обливщик (ялтыратучы, чүлмәккә, чынаякка глазурь йөгертүче эшче).

**ОБЛИГАЦИО'ННЫЙ** *экон.* — облигацияле; *облигационные займы* — облигацияле заёмнар.

**ОБЛИГА'ЦИЯ** *ж. экон.* — облигация.

**ОБЛИЗА'ТЬ** *сов.* — ялап алу, ялап чыгу, ялап чистарту. ◇ **Пальчики оближешь** *разг.* — телеңне йотарсың. **Облизать губы** — тирәкереген йоту (тәмле әйбер ашар алдыннан авыз суы килү).

**ОБЛИЗА'ТЬСЯ** *сов.* — 1. иреннәрен ялау (кеше турында); ялану (хайван турында); 2. *разг. фам.* (*остаться ни с чем в ожиданиях*) ымсынып калу, өмете бушка чыгу, коры калу.

**ОБЛИЗНУ'ТЬ** *сов. однокр. разг.* — ялап алу, ялап кую.

**ОБЛИЗНУ'ТЬСЯ** *сов. однокр. простореч.* — яланып кую, иреннәрен ялап кую; *он облизнулся* — ул яланып куйды, иреннәрен ялап куйды.

**ОБЛИ'ЗЫВАТЬ** *несов.* — к. облизать.

**ОБЛИ'ЗЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. облизаться; 2. *перен.* (*предвкушать что-н. вкусное*) ымсынып көтеп тору, ымсынып тору; 3. *разг. фам.* (*зариться*) күз кызыгу, кызыгып карап тору.

**О'БЛИК** *м. книж.* — йөз, чырай, кыяфәт, тышкы күренеш; *нравственный облик человека* — кешенең әхлакый йөзе.

**ОБЛИНЯ'ЛЫЙ** *простореч.* — 1. унган, төсе киткән; 2. йонын, ябагасын койган.

**ОБЛИНЯ'ТЬ** *сов. разг.* — 1. уңу, төсе китү; 2. йонын кою, ябагасын кою; кабыгын салу.

**ОБЛИПА'ТЬ** *несов. разг.* — к. облипнуть.

**ОБЛИ'ПНУТЬ** *сов. разг.* — ябышу, ябышып бетү, сыланып бетү (төрле яктан).

**ОБЛИСПОЛКО'М** *м.*—(областной исполнительный комитет) өлкә башкарма комитеты.

**ОБЛИ'ТЬ** *сов.* — 1. кою, өстенә сибеп чылату, ...-га коендыру; *облить водой (кого-что)* өстенә су кою, башыннан су кою, суга коендыру; өстенә су сибеп чылату; *облить водой голову* — башка (башына) су кою; 2. өстенә түгү; өстенә түгеп, пычратып (буяп) бетерү; *облить скатерть супом* — ашъяулыкка шулпа түгү; ашъяулыкны шулпа түгеп пычратып бетерү; *облить скатерть чернилами* — ашъяулыкка кара түгеп буяп бетерү; 3. *спец.* тышына йөгертеп (сөртеп, сибеп) чыгу, тышын... белән каплау; *облить горшок глазурью* — чүлмәкнең тышын глазурь белән каплау; чүлмәкнең тышына глазурь йөгертеп чыгу; 4. *перен.* ... белән каплану, ...-га бату, ...-га чуму, ... белән тулу, ...-га тулу; *зала была облита серебряным светом луны* — зал эче айның көмеш яктысы белән тулган иде, залга айның көмеш яктысы тулган иде; *лесная поляна облита яркими лучами солнца* — урман аланы кояшның якты нурларына чумган. ◇ **Облить грязью** — пычрак ташлау, яла ягу. **Облить презрением** *книж.* — җирәнеп карау, нәфрәтле караш ташлау.

**ОБЛИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. коену, үз өстенә су сибү; *облиться холодной водой* — үз өстенә салкын су сибү; 2. бату, буялу; *облиться потом* — тиргә бату; *облиться слезами* — яшь түгү, күз яше түгү.

**ОБЛИЦЕВА'ТЬ** *сов. спец.* — тышлау, каплау (өйне такта, штукатурка белән, базны кәс белән һ. б.); *станции Московского метро облицованы мрамором* — Москва метросы станцияләренең стеналары мәрмәр белән капланган.

**ОБЛИЦО'ВКА** *ж. спец.* — 1. к. облицевать; 2. тышлык, тыш.

**ОБЛИЦО'ВОЧНЫЙ** *спец.* — тышлык..., тышлый торган; *облицовочные плитки* — тышлый торган плиткалар.

**ОБЛИЦО'ВЩИК** *м. спец.* — облицовщик (биналарның стеналарын, мичләрен һ. б. мәрмәр кебек асыл таш яки төрле төстәге кирпечләр белән каплаучы).

**ОБЛИЦО'ВЫВАТЬ** *несов. спец.* — к. облицевать.

**ОБЛИЦО'ВЫВАТЬСЯ** *несов. страд. спец.* — тышлану, каплану.

**ОБЛИЧА'ТЬ** *несов. книж.* — 1. йөзен ачу, фаш итү, гаебен ачу; *обличать политических врагов* — политик дошманнарның йөзен ачу; 2. ачу, күрсәтү; *всё это обличает в нём талант* — болар барысы да аның талантлы булуын күрсәтә.

**ОБЛИЧА'ТЬСЯ** *несов. страд. книж.* — йөзе ачылу, фаш ителү, гаебе ачылу.

**ОБЛИЧИ'ТЕЛЬ** *м. книж. ритор.* — фаш итүче, гаебен ачучы, ялганын ачучы.

**ОБЛИЧИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.* — фаш иткеч, фаш итә торган, гаебен күрсәтеп бирә торган, ялганын ача торган, йөзен ача торган; *обличительная литература* — фаш итә торган әдәбият.

**ОБЛИЧИ'ТЬ** *сов. книж.* — к. обличать 1.

**ОБЛИ'ЧЬЕ** *ср.* — 1. *разг. обл.* йөз, бит, тышкы күренеш, кыяфәт; 2. *устар.* (*маска*) битлек; 3. *перен. книж. ритор.* йөз; *звериное обличье фашизма* — фашизмның ерткыч йөзе.

**ОБЛОБЫЗА'ТЬ** *сов. книж. устар. теперь шутл.* — үбү, кат-кат үбү.

**ОБЛОБЫЗА'ТЬСЯ** *сов. книж. устар. теперь шутл.* — үбешү, чупылдатып үбешү.

**ОБЛО'В** *м. спец.* — 1. к. обловить; 2. (*улов*) тотылган балык, (билгеле вакыт эчендә) тотылган балыкның күләме.

**ОБЛОВИ'ТЬ** *сов.* — тотып бетерү; *обловить озеро* — күлдәге балыкны тотып бетерү.

**ОБЛО'Г** *м.*, **ОБЛО'ГА** *ж. обл.* — кысыр җир (ташландык хәлдә калып чирәмгә әйләнгән сөрү җире).

**ОБЛОЖЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — 1. к. обложить 5; 2. *офиц.* имана, налог, салым; 3. *устар.* камап алу; *обложение крепости* — крепостьны камап алу.

**ОБЛО'ЖЕЧНЫЙ** *спец.* — тышлык...; *обложечная бумага* — тышлык кәгазь.

**ОБЛОЖИ'ТЬ** *сов.* — 1. (*положить кругом*) тирәли салып чыгу; куеп чыгу; *обложить больного подушками* — авыруның як-ягына мендәрләр куеп чыгу; 2. каплау, каплап алу; *туча обложила горизонт* — горизонтны болыт каплап алды; 3. *воен.* чолгап алу, камап алу; *обложить неприятеля* — дошманны чолгап алу; 4. *охот.* камап алу; *обложить медведя в берлоге* — аюны өнендә камап алу; 5. *офиц.* салым салу, налог салу; *обложить доход с торговли* — сәүдәдән килгән доходка налог салу; 6. *вульг.* (*грубо обругать*) сүгеп ташлау, тупас рәвештә сүгеп ташлау.

**ОБЛОЖИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. тирә-ягына кую; *он обложился подушками* — ул тирәягына мендәрләр куйган; 2. *простореч.* ялгышып салып кую; *вероятно, я какнибудь обложился, положил в левый карман* — бәлки, мин ялгышып сул кесәгә салып куйганмындыр.

**ОБЛО'ЖКА** *ж.* — тыш, тышлык (мәсәлән, китап, дәфтәр тышлыгы).

**ОБЛОЖНО'Й** *разг. обл.*: обложной дождь — күк йөзен томалап яуган яңгыр.

**ОБЛОКА'ЧИВАТЬ** *несов.* — к. облокотить.

**ОБЛОКА'ЧИВАТЬСЯ** *несов.* — к. облокотиться.

**ОБЛОКОТИ'ТЬ** *сов.* — таяну, терсәкне терәү.

**ОБЛОКОТИ'ТЬСЯ** *сов.* — терсәккә таяну, терсәк белән таяну; *облокотился на стол* — терсәге белән өстәлгә таянды.

**ОБЛО'М** *м.* — 1. *только ед.* к. обломить,

обломиться; 2. (*место, от которого что-н. отломлено*) сынган урын; 3. *архит.* архитектурада вак деталь; 4. *истор.* чыгынты (борынгы крепость стенасының алга чыгып торган урыны); 5. *разг. пренебр.* кусәк (зур гәүдәле, тәрбиясез һәм аңгыра кеше).

**ОБЛОМА'ТЬ** *сов.* — 1. (*отломать кругом*) (тирәли) сындырып чыгу; *обломать сучья дерева* — агачның ботакларын сындырып чыгу; 2. *простореч. фам.* кыйнау, тукмау, сындыру; *я ей бока обломаю* — мин аның кабыргаларын сындырырмын; 3. *простореч.* үгетләп ипкә китерү, сүзгә күндерү (кире кешене); *обломать упрямца* — кире кешене сүзгә күндерү; 4. *простореч.* башкару, башкарып чыгу, эшләү; *обломаю дел много, не умру* (Тургенев) — күп эшләр эшләрмен, үлмәм. ◇ **Обломать дельце** *простореч.* — эшне аударып ташлау.

**ОБЛОМА'ТЬСЯ** *сов.* — сыну, сынып төшү, ватылып төшү; *ручки кресел обломались* — креслоларның култыксалары сынып төшкән.

**ОБЛОМИ'ТЬ** *сов.* — сындырып алу, сындырып төшерү.

**ОБЛОМИ'ТЬСЯ** *сов.* — сыну, сынып төшү; *сук обломился* — ботак сынып төшкән.

**ОБЛО'МОВЕЦ** *м. книж. неодобр.* — обломовчы (обломовчылыкка бирелгән кеше, ялкау кеше, сүлпән, ихтыярсыз, эшлексез кеше).

**ОБЛО'МОВСКИЙ** — обломовчылык...-ы; *обломовские привычки* — обломовчылык гадәтләре.

**ОБЛО'МОВЩИНА** *ж. мн.* нет, *книж. публиц.* — обломовчылык (ялкаулык, сүлпәнлек, эшсезлек, ихтыярсызлык; рус язучысы Гончаровның „Обломов" дигән романындагы төп герое исеменнән алынган).

**ОБЛО'МОК** *м.* — сынып төшкән кисәк, ватык, сынык; *обломки стула* — урындык ватыклары; 2. *перен.* калдык; *обломки прошлого* — борынгылык калдыклары, борынгының калдыклары.

**ОБЛО'ПАТЬСЯ** *сов. простореч. вульг.* — тыгыну, шартлаганчы ашау.

**ОБЛУПИ'ТЬ** *сов.* — 1. кубарып алу, кубарып ташлау, әрчеп ташлау, әрчү (кабыгын, кайрысын), каезлау; 2. *перен. простореч. фам.* (*ограбить, взять непомерно дорого*) талау; артык кыйммәт бәягә сату. ◇ **Облупить, как липку** — к. липка.

**ОБЛУПИ'ТЬСЯ** *сов.* — кубып төшү, кубу; *краска облупилась* — буявы кубып төшкән.

**ОБЛУ'ПЛИВАТЬ** *несов.* — 1. к. лупить 2; 2. *простореч.* к. облупить 2.

**ОБЛУ'ПЛИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. лупиться 1, 2; 2. *страд.* кабыгы кубарылу, әрчелү.

**ОБЛУПЛЯ'ТЬ** *несов. простореч.* — к. лупить 2.

**ОБЛУПЛЯ'ТЬСЯ** *несов. простореч.* — 1. к. лупиться 1, 2; 2. *страд.* кабыгы кубарылу, каезлану, әрчелү.

**ОБЛУЧО'К** *м.* — кузла, ат башы (тарантасның, кашавай чананың кучер утыра торган урыны).

**ОБЛУ'ЩИВАТЬ** *несов.* — к. лущить 2.

**ОБЛУЩИ'ТЬ** *сов.* — к. лущить 2.

**ОБЛЫГА'ТЬ** *несов. устар.* — яла ягу.

**ОБЛЫ'ЖНЫЙ**, *простореч. устар.* — ялган, нахак, яла яга торган; *облыжные речи* — ялган речьләр, нахак сүзләр.

**ОБЛЫСЕ'ТЬ** *сов.* — пеләшләнү, чәч коелып бетү.

**ОБЛЮБИ'ТЬ** *сов. простореч.* — сөю, гашыйк булу.

**ОБЛЮБОВА'ТЬ** *сов.* — күңелгә ошаганын сайлап алу, күңелгә ошату.

**ОБЛЮБО'ВЫВАТЬ** *несов.* — к. облюбовать.

**ОБЛЮБО'ВЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — күңелгә ошаганы сайлап алыну.

**ОБЛЯ'ПАТЬ** *сов. простореч.* — чәчрәтеп, пычратып бетерү; *обляпать грязью сапоги* — итекне пычрак чәчрәтеп, пычратып бетерү.

**ОБЛЯ'ПЫВАТЬ** *несов. простореч.* — к. обляпать.

**ОБМА'ЗАТЬ** *сов.* — 1. сылап чыгу; *обмазать печку глиной* — мичне балчык белән сылап чыгу; 2. буяп бетерү, пычратып бетерү; *обмазать лицо сажей* — битне корымга буяп бетерү.

**ОБМА'ЗАТЬСЯ** *сов. разг.* — буялып бетү, пычранып бетү; *обмазаться дёгтем* — дегеткә буялып бетү.

**ОБМА'ЗКА** *ж.* — 1. (*действие*) к. обмазать; 2. *спец.* (*вещество, которым обмазывают*) сылауга китә торган әйбер.

**ОБМА'ЗЫВАТЬ** *несов.* — к. обмазать.

**ОБМА'ЗЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. *разг.* к. обмазаться; 2. *страд.* буяп бетерелү, пычратып бетерелү.

**ОБМА'КИВАТЬ** *несов.* — к. обмакнуть.

**ОБМА'КИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — манчылу, манылу, манчып алыну.

**ОБМАКНУ'ТЬ** *сов.* — манып алу, манчып алу.

**ОБМА'ЛЫВАТЬ** *несов.* — к. обмолоть.

**ОБМА'ЛЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — тарттырылу (арыш, бодай һ. б. турында).

**ОБМА'Н** *м. мн.* нет — 1. (*действие*) к. обмануть; 2. (*ложь*) ялган. ◇ **Ввести в обман** — ялгыштыру, ялгыш юлга кертү. **Не дамся в обман** — үземне алдатмам. **Обман зрения** — күрү ялгышлыгы. **Обман чувств** — тойгыларның алдавы.

**ОБМА'ННЫЙ** — алдау...-ы; *обманным образом* — алдау юлы белән.

**ОБМАНУ'ТЬ** *сов.* — 1. алдау; *вас обманули* — сезне алдаганнар; 2. (*нарушить обещание*) сүзендә тормау, вәгъдәсен үтәмәү; 3. (*изменить мужу, жене*) алдау, хыянәт итү.

**ОБМАНУ'ТЬСЯ** *сов. книж.* — алдану.

**ОБМА'НЧИВОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — алдаучанлык.

**ОБМА'НЧИВЫЙ** — ышанычсыз, алдаучан, алдый торган; *обманчивый вид* — алдаучан

кыяфәт. ◇ К чему обманчивая нежность? — Нигә кирәк ялган назлылык?

**ОБМА'НЩИК** *м.*, **ОБМА'НЩИЦА** *ж.* — алдакчы, ялганчы.

**ОБМА'НЫВАТЬ** *несов.* — к. обмануть.

**ОБМА'НЫВАТЬСЯ** *несов.* — к. обмануться.

**ОБМАРА'ТЬ** *сов.* — пычратып бетерү, буяп бетерү; *обмарать рубаху* — күлмәкне пычратып бетерү.

**ОБМАРА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. пычранып бетү, буялып бетү; 2. *эвф. (испражняться под себя)* аска җибәрү (балалар турында әйтелә).

**ОБМА'РЫВАТЬ** *несов. разг.* — к. обмарать.

**ОБМА'РЫВАТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. к. обмараться; 2. *страд.* пычратып бетерелү, буяп бетерелү.

**ОБМА'СЛИВАТЬ** *несов. разг.* — к. обмаслить.

**ОБМА'СЛИВАТЬСЯ** *несов. разг.*—1. к. обмаслиться; 2. *страд.* майлану, майга буялу.

**ОБМА'СЛИТЬ** *сов.* — 1. *(обмазать маслом)* майлау; 2. *(замаслить)* майга буяу, майга буяп бетерү.

**ОБМА'СЛИТЬСЯ** *сов. разг.* — майлану, майланып бетү.

**ОБМА'ТЫВАТЬ** *несов.* — к. обмотать.

**ОБМА'ТЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. *разг.* к. обмотаться; 2. *страд.* уралу, чорналу.

**ОБМАХА'ТЬ** *сов. простореч.* — йөреп чыгу, бик тиз арада йөреп чыгу; *в полчаса обмахал весь город* — ярты сәгатьтә бөтен шәһәрне йөреп чыктым.

**ОБМА'ХИВАТЬ** I *несов. простореч.* — к. обмахать.

**ОБМА'ХИВАТЬ** II *несов.* — к. обмахнуть.

**ОБМА'ХИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. обмахнуться; 2. *страд.* селкеп төшерелү, себереп төшерелү.

**ОБМАХНУ'ТЬ** *сов.* — 1. җилпү, җилләндереп алу; *обмахнуть лицо веером* — битне җилпәзә белән җилләндереп алу; 2. селкеп төшерү; *обмахнуть сор со скатерти* — эскәтердән чүпне селкеп төшерү; 3. сөртеп алу; *обмахнуть полку* — шүрлекне сөртеп алу.

**ОБМАХНУ'ТЬСЯ** *сов.* — җилләнеп алу (мәсәлән, җилпәзә белән).

**ОБМА'ЧИВАТЬ** *несов.* — к. обмочить.

**ОБМА'ЧИВАТЬСЯ** *несов. простореч.* — 1. к. обмочиться; 2. *страд.* чылатылу.

**ОБМЕБЛИРОВА'ТЬ** *сов.* — к. меблировать.

**ОБМЕБЛИРОВА'ТЬСЯ** *сов.* — (бүлмәне, квартираны) җиһазлау.

**ОБМЕБЛИРО'ВЫВАТЬ** *несов.* — к. обмеблировать.

**ОБМЕБЛИРО'ВЫВАТЬСЯ** *несов.* — к. обмеблироваться.

**ОБМЕЖЕВА'ТЬ** *сов. устар. спец.* — межалау, межа белән бүлеп (әйләндереп) алу, ызан сызып чыгу.

**ОБМЕЖЁВЫВА'ТЬ** *несов. спец. устар.* — к. обмежевать.

**ОБМЕЖЁВЫВАТЬСЯ** *несов. страд. спец. устар.* — межалану, межа ярылу, межа белән әйләндерелеп алыну.

**ОБМЕЛЕ'ЛЫЙ** *простореч.* — саеккан (күл, елга турында).

**ОБМЕЛЕ'ТЬ** *сов.* — 1. саегу (күл, елга турында); 2. *спец. (сесть на мель)* комга утыру, сайлыкка утыру (баржа, көймә, пароход турында); 3. *перен. книж. (стать ничтожным, измельчать)* әһәмиятен югалту, әһәмиятсезләнү.

**ОБМЕЛИ'ТЬ** *сов. разг.* — акбурга буяу, акбурга буяп бетерү.

**ОБМЕЛЬЧА'ТЬ** *сов.* — 1. *разг.* к. измельчать; 2. *обл.* к. обмелеть.

**ОБМЕ'Н** *м. мн.* нет — алмашу, алышу, алмашыну; *обмен веществ* — матдәләр алмашынуы; *обмен мнений* — фикер алышу.

**ОБМЕ'НИВАТЬ** *несов.* — к. обменять, обменить.

**ОБМЕ'НИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. обменяться; 2. *страд.* алмаштырылу; ялгыш алмаштырылу.

**ОБМЕНИ'ТЬ** *сов.* — 1. *разг.* ялгыш алмаштырып алып китү, ... урынына алып китү, ялгыш киеп китү (кеше киемен, әйберен); *когда расходились, кто-то обменил новые галоши на старые* — таралышкан чакта, кемдер яңа галош урынына иске галош киеп киткән; 2. *простореч.* к. обменять.

**ОБМЕНИ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— ялгышып алмаштыру; *обмениться галошами* — ялгышып галошларны алмаштыру.

**ОБМЕ'ННЫЙ** *спец.* — 1. алмаштырыла торган; *обменные экземпляры книги* — китапның алмаштырыла торган данәләре; 2. алмаштыру...-ы; *обменный пункт* — алмаштыру пункты.

**ОБМЕНЯ'ТЬ** *сов.*—алмашу, алышу, алыштыру; *обменять собак* — этләрне алышу; *обменять книгу в библиотеке* — китапханәдә китапны алыштыру.

**ОБМЕНЯ'ТЬСЯ** *сов.*— алмашу; *обменяться книгами* — китапларны алмашу. ◇ **Обменяться поклонами** — исәнләшү. **Обменяться взглядами** — карашып алу. **Обменяться опытом** — тәҗрибә уртаклашу. **Обменяться мнениями** — фикер алышу.

**ОБМЕ'Р** *м.* — 1. үлчәп алу, үлчәп чыгу; 2. үлчәүдә алдау.

**ОБМЕРЕ'ТЬ** *сов.* — катып калу; *я обмер от испуга* — куркуымнан катып калдым.

**ОБМЕРЗА'ТЬ** *несов.* — к. обмёрзнуть.

**ОБМЁРЗЛЫЙ** *простореч.* — бозланган, боз каткан; *обмёрзлые ступеньки* — боз каткан баскычлар.

**ОБМЁРЗНУТЬ** *сов.* — 1. тирәли бозлану, боз кату; *обмёрзли усы, борода ямщика* — ямщикның сакал-мыекларына боз каткан; 2. *разг. (сильно озябнуть)* туңу, өшү, туңып бетү, өшеп бетү.

**ОБМЕ'РИВАТЬ** *несов.* — к. обмерить.

**ОБМЕ'РИВАТЬСЯ** *несов.*—1. к. обмериться; 2. *страд.* үлчәп алыну, үлчәп чыгылу.

**ОБМЕ'РИТЬ** *сов. разг.* — 1. үлчәп чыгу; *обмерить земельный участок* — җир участогын үлчәп чыгу; 2. *разг.* үлчәгәндә алдау, ким үлчәү.

**ОБМЕ'РИТЬСЯ** *сов. разг.* — үлчәгәндә ялгышу.

**ОБМЕ'РКА** *ж. мн.* нет, *простореч.* — к. обмерить 1.

**ОБМЕ'РОК** *м. спец.* — 1. *(недомерок)* кечкенә үлчәүле кием, кечкенә үлчәүле аяк киеме; 2. *(остаток после измерения)* калдык (үлчәгәннән соң калган өлеш).

**ОБМЕ'РЩИК** *м. спец.* — үлчәүче.

**ОБМЕ'РЫШ** *м. обл.* — 1. к. обмерок; 2. *(человек низкого роста)* карсак кеше.

**ОБМЕ'РЯТЬ** *сов.* — к. обмерить.

**ОБМЕРЯ'ТЬ** *несов.* — к. обмерить.

**ОБМЕ'РЯТЬСЯ** *сов.* — к. обмериться.

**ОБМЕРЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — үлчәп алыну, үлчәп чыгылу; үлчәгәндә алдану.

**ОБМЕСТИ'** *сов.* — себереп алу, себереп төшерү; *обмести пыль с потолка* — түшәмнән тузанны себереп төшерү.

**ОБМЁТ** I *м. охот.* — җәнлек аулый торган ятьмә.

**ОБМЁТ** II *м. обл.* — чүпле он (тегермәндә себереп җыелган он).

**ОБМЁТ** III *м. обл.* — чүп-чар (озак вакытлар буена өй, сарай һ. б. тирәсенә өелгән туфрак, чүп).

**ОБМЕТА'ТЬ** I *несов.* — к. обмести.

**ОБМЕТА'ТЬ** II *сов.* — 1. *порт. (обшить края стёжками)* типчеп чыгу, күкләп чыгу; 2. *обл. охот. (закидывая верёвку, завязать)* элмәкле бау ыргытып эләктереп алу; 3. чабыру; *губы обметало* — ирен чабырган.

**ОБМЕТА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — себереп төшерелү.

**ОБМЕ'ТИТЬ** *сов. простореч.* — билге куеп чыгу.

**ОБМЁТЫВАТЬ** *несов.* — к. обметать II.

**ОБМЁТЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — типчеп чыгылу.

**ОБМЕЧА'ТЬ** *несов. простореч.* — к. обметить.

**ОБМИ'Н** *м. мн.* нет, *спец.* — к. обмять, обминать.

**ОБМИНА'ТЬ** *несов.* — к. обмять.

**ОБМИНА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. обмяться; 2. *страд.* тыгызландырылу, баскалап, кыскалап төзәтелү, кирәкле формага кертелү.

**ОБМИРА'НИЕ** *ср.* — 1. *только ед. (действие)* к. обмирать; 2. *(полуобморочное состояние)* ярым һушсызлык хәлендә булу.

**ОБМИРА'ТЬ** *несов. разг.* — к. обмереть.

**ОБМИШУ'ЛИВАТЬ** *несов. простореч.* — к. обмишулить.

**ОБМИШУ'ЛИВАТЬСЯ** *несов. простореч.* — к. обмишулиться.

**ОБМИШУ'ЛИТЬ** *сов. простореч.* — алдау, утырту.

**ОБМИШУ'ЛИТЬСЯ** *сов. простореч.* — ялгышу, алдану.

**ОБМОЗГОВА'ТЬ** *сов. простореч.* — яхшылап уйлау, уйлап карау.

**ОБМОЗГО'ВЫВАТЬ** *несов. простореч.* — к. обмозговать.

**ОБМОКА'ТЬ** *несов. разг.* — к. обмокнуть.

**ОБМО'КНУТЬ** *сов. разг.* — чыланып бетү, юешләнеп бетү.

**ОБМОКНУ'ТЬ** *сов. разг.* — к. обмакнуть.

**ОБМО'Л** *м. мн.* нет, *с.-х.* — 1. *(действие)* к. обмолоть; 2. *(количество обмолотого зерна)* онга тартылган ашлыкның күләме.

**ОБМОЛА'ЧИВАТЬ** *несов. с.-х.* — к. обмолотить.

**ОБМОЛА'ЧИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. *обл.* к. обмолотиться; 2. *страд. с.-х.* сугылып бетү (ашлык).

**ОБМО'ЛВИТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. *(оговориться)* ялгыш әйтү, ялгыш әйтеп салу, ялгыш әйтеп кую; 2. *(сказать что-н.)* берәр сүз әйтеп кую. ◇ **Не обмолвился ни словом** — бер сүз дә дәшмәде.

**ОБМО'ЛВКА** *ж.* — ялгыш ычкынган сүз, уйламыйча әйтелгән сүз.

**ОБМОЛО'Т** *м. мн.* нет, *с.-х.* — 1. к. обмолотить, обмолачивать; 2. *(количество обмолоченного зерна)* төшем, сугып алынган ашлыкның күләме.

**ОБМОЛОТИ'ТЬ** *сов. с.-х.* — сугып бетерү (ашлыкны).

**ОБМОЛОТИ'ТЬСЯ** *сов. обл.* — сугып бетерү; ашлык сугу эшен тәмамлау.

**ОБМОЛО'ТОК** *м. обл.* — очык, кибәк, башак очы.

**ОБМОЛО'ТОЧНЫЙ** *с.-х.* — ашлык сугу ...-ы; *обмолоточный пункт* — ашлык сугу пункты.

**ОБМОЛО'ТЬ** *сов. обл.* — онга тарту.

**ОБМОРА'ЖИВАТЬ** *несов.* — к. обморозить.

**ОБМОРА'ЖИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. *разг.* к. обморозиться; 2. *страд.* тундырылу, өшетелү.

**ОБМОРА'ЧИВАТЬ** *несов. разг.* — к. морочить.

**ОБМОРО'ЗИТЬ** *сов.* — 1. өшетү; *обморозить руки* — кулларны өшетү; 2. *обл.* тундыру; *обморозить рыбу* — балыкны тундыру.

**ОБМОРО'ЗИТЬСЯ** *сов.* — бик нык өшү, туну, тунып бетү.

**О'БМОРОК** *м.* — һуш китү, һуштан язу; *упасть в обморок* — һуш китеп егылу.

**ОБМОРО'ЧИТЬ** *сов. разг.* — баш катыру, баш катырып бетерү.

**ОБМОТА'ТЬ** *сов.* — урау, урап кую, чорнап кую; *обмотать голову полотенцем* — башка сөлге урап кую.

**ОБМО'ТКА** *ж.* — 1. *(действие) только ед.* к. обмотать; 2. обмотка (а. электр чыбыгын изоляцияләү өчен урала торган тасма; б. *только мн.* балтырга чорный торган киң тасма).

**ОБМОЧИ'ТЬ** *сов.* — чылату, чылатып алу.

**ОБМОЧИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. чылану, чыланып бетү; 2. *фам. (испустить мочу под себя)* аска җибәрү.

**ОБМУНДИРОВА'НИЕ** *ср.* — 1. *только ед. (действие)* к. обмундировать; 2. *(форменная одежда)* форменный кием, обмундирование.

**ОБМУНДИРОВА'ТЬ** *сов.* — 1. киендерү, кием бирү (тиешле формадагы киемнәр белән тәэмин итү); 2. *разг. шутл.* баштанаяк киендерү (тулы комплект кием белән тәэмин итү).

**ОБМУНДИРОВА'ТЬСЯ** *сов.* — 1. обмун-

дирование алу; 2. *разг. шутл.* барлык кирәк булган кием-салымны булдыру.

**ОБМУНДИРО'ВОЧНЫЙ** *офиц.* — обмундирование алу өчен билгеләнгән; *обмундировочные деньги* — обмундирование алу өчен билгеләнгән акча.

**ОБМУНДИРО'ВЫВАТЬ** *несов.* — к. обмундировать.

**ОБМУНДИРО'ВЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. обмундироваться; 2. *страд.* обмундирование бирелү.

**ОБМУРОВА'ТЬ** *сов. тех.* — кирпеч стена эченә ныгытып урнаштыру (мәс. казанны).

**ОБМУ'СЛИТЬ** *сов. простореч.* — селәгәйләү, төкерекләү; *обмуслить нитку* — жепне төкерекләү.

**ОБМУСО'ЛИТЬ** *сов. простореч.* — к. обмуслить.

**ОБМЫВА'НИЕ** *ср.* — 1. *только ед.* к. обмывать; 2. *спец.* эремә (юыну өчен хәзерләнгән махсус сыекча).

**ОБМЫВА'ТЬ** *несов.* — к. обмыть.

**ОБМЫВА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. обмыться; 2. *страд.* юылу.

**ОБМЫ'ВКА** *ж. простореч.* — к. обмывание.

**ОБМЫ'ЗГАТЬ** *сов. простореч.* — пычратып бетерү, эштән чыгарып бетерү.

**ОБМЫ'ЗГАТЬСЯ** *сов. простореч.* — пычранып бетү, шакшыланып бетү, эштән чыгу; *подол платья обмызгался* — күлмәкнең итәге пычранып беткән.

**ОБМЫ'ЛИВАТЬ** *несов.* — к. обмылить.

**ОБМЫ'ЛИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. обмылиться; 2. *страд.* сабынландырылу.

**ОБМЫ'ЛИТЬ** *сов.* — 1. сабынлау, сабын күбеге сөртү; 2. *хим.* сабынга әверелдерү (май матдәләрен сабынга әйләндерү өчен химик реакция ясау).

**ОБМЫ'ЛИТЬСЯ** *сов.* — 1. *разг.* (*обмылить себя*) сабынлану; сабын сөртү; 2. *разг.* (юылып) кимү; *мыло уже обмылилось* — сабын (юылып) кимегән; 3. *хим.* сабынга әверелү (май матдәләренең химик реакция аркасында сабынга әйләнүе).

**ОБМЫ'ЛОК** *м. простореч.* — сабын калдыгы, сабын кисәге.

**ОБМЫ'ТЬ** *сов.* — 1. юу, юып тазарту; *обмыть рану* — яраны юып тазарту; 2. *простореч.* к. обстирать.

**ОБМЫ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. юыну; 2. юылып төшү; *от дождя пыль с листьев обмылась* — яфраклардагы тузан яңгыр белән юылып төшкән, яңгыр яфраклардагы тузанны юып төшергән.

**ОБМЯКА'ТЬ** *несов. разг.* — к. обмякнуть.

**ОБМЯ'КНУТЬ** *сов. разг.* — 1. йомшару, изелү; *глина под дождём обмякла* — балчык яңгырдан изелгән; 2. *перен.* җебү, изрәү, мәлҗерәп киту, мәлҗерәү, җебеп киту; *старик совсем обмяк* — карт бөтенләй изрәгән, мәлҗерәгән.

**ОБМЯ'ТЬ** *сов.* — 1. *(о постели)* кабарту, иплəү; 2. *(о сене и т. п.)* тыгызлау.

**ОБМЯ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. ипләнү; җайлану; *постель обмялась* — урын ипләнгән; 2. тыгызлану, басылу; *сено обмялось* — печән тыгызланган, басылган.

**ОБНАГЛЕ'ТЬ** *сов.* — оятсызлану, оятын югалту, оятсызланып бетү; *он совсем обнаглел* — ул бөтенләй оятсызланган.

**ОБНАГЛИ'ТЬ** *сов.* — оятсызландыру.

**ОБНАДЁЖИВАТЬ** *несов.* — к. обнадёжить.

**ОБНАДЁЖИТЬ** *сов.* — өметләндерү, ышандыру, вәгъдә бирү.

**ОБНАЖА'ТЬ** *несов.* — к. обнажить.

**ОБНАЖА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. обнажиться; 2. *страд.* ялангач калдырылу; 3. *страд. перен.* фаш ителү.

**ОБНАЖИ'ТЬ** *сов. книж.* — 1. ялангач калдыру; 2. ачу, чыгару; *обнажить нерв* — нервны ачу; *обнажить шпагу* — кылычны кынысыннан чыгару; 3. *перен.* ачу, фаш итү; *обнажить методы буржуазной дипломатии* — буржуазия дипломатиясенең методларын фаш итү.

**ОБНАЖИ'ТЬСЯ** *сов. книж.* — 1. *(раздеться, оголиться)* ялангачлану, ялангач калу, шәрәләнү; *лес обнажился, поля опустели* (Некрасов) — урман ялангачланды, кырлар буш калды; 2. ачылу; *нерв обнажился* — нерв ачылды; 3. *перен.* фаш ителү, ачылу; *вся подноготная обнажилась* — бөтен эчке серләре ачылды, бөтен әшәкелекләре ачылды.

**ОБНАРО'ДОВАТЬ** *сов. книж.* — халыкка белдерү, игълан итү; дөньяга чыгару; *обнародовать указ* — указны халыкка игълан итү.

**ОБНАРУ'ЖИВАТЬ** *несов.* — к. обнаружить.

**ОБНАРУ'ЖИВАТЬСЯ** *несов.* — к. обнаружиться.

**ОБНАРУ'ЖИТЬ** *сов.* — 1. күрсәтү, белдерү; *обнаружить радость* — шатлык белдерү, шатлык күрсәтү; *обнаружить способность* — сәләтлек күрсәтү; 2. табу; *обнаружить пропавшую вещь* — югалган әйберне табу; 3. табу, серенә төшенү, серен табу (белү); *обнаружить действительную причину болезни* — авыруның чын сәбәбен табу; 4. белү, сизеп алу, ачу; *обнаружить пропажу документов* — документларның югалуын белү (ачу), документларның югалган икәнлеген сизеп алу.

**ОБНАРУ'ЖИТЬСЯ** *сов.* — 1. табылу, беленү, килеп чыгу, ...-а башлау; *обнаружились новые факты* — яңа фактлар килеп чыкты; *у него обнаружился интерес к музыке* — ул музыка белән кызыксына башлады; 2. беленү, билгеле булу; *обнаружилась пропажа денег* — акча югалуы билгеле булды. ◇ На круглом, толстом лице его обнаружились угловатые скулы — аның түгәрәк тулы йөзендә почмакланып янак сөякләре күренә башлады.

**ОБНА'ШИВАТЬ** I *несов.* — к. обносить I.

**ОБНА'ШИВАТЬ** II *несов.* — к. обносить II.

**ОБНА'ШИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. к. обноситься I; 2. *страд.* киеп туздырып бетерелү, сәләмәләндереп бетерелү.

**ОБНЕСТИ'** *сов.* — 1. күтәреп йөртеп чы-

гу; *бабушка сначала велела обнести себя по всем залам* — әби башта үзен бөтен заллар аша күтәреп йөртеп чыгарга кушты; 2. *устар. (разнести всем)* таратып чыгу; 3. *(обойдя, всех угостить)* сыйлап чыгу; 4. *(обходя с угощением, пропустить, пронести мимо кого-н.)* буш калдыру, бирми үтеп китү; 5. әйләндереп алу, әйләнәсен киртәләп алу; *обнести сад забором* — бакчаны койма белән әйләндереп алу; 6. *устар. (опорочить, оговорить)* яла ягу, өстенә сөйләү, яман атын сату.

**ОБНИЗА'ТЬ** *сов. разг.* — тезеп чыгу; *обнизать ленту бисером* — тасмага сәйлән тезеп чыгу.

**ОБНИ'ЗЫВАТЬ** *несов. разг.* — к. обнизать.

**ОБНИ'ЗЫВАТЬСЯ** *несов. страд. разг.* — тезеп чыгылу.

**ОБНИМА'ТЬ** *несов.* — к. обнять и объять.

**ОБНИМА'ТЬСЯ** *несов.* — к. обняться.

**ОБНИ'МКА** *ж.*: **в обнимку** *простореч. фам.* — кочаклашып; *уснули в обнимку* — кочаклашып йоклап киттеләр.

**ОБНИЩА'ЛЫЙ** — хәерчелеккә төшкән, фәкыйрьлеккә төшкән.

**ОБНИЩА'ТЬ** *сов. книж.* — бөлгенлеккә төшү, хәерчелеккә төшү.

**ОБНО'ВА** *ж. разг.* — яңа әйбер, яңа кием.

**ОБНОВИ'ТЕЛЬ** *м. книж.* — яңалык кертүче, яңартучы; *обновитель искусства* — сәнгатькә яңалык кертүче.

**ОБНОВИ'ТЬ** *сов.* — 1. яңарту; *лес обновил свою листву* — урман үзенең яфракларын яңартты; 2. яңарту, яңалык кертү, яңалык кертеп үзгәртү; *обновить методы работы* — эш методларын яңарту; 3. *разг.* яңарту, төзәтү; *обновить крышу* — түбәне яңарту; *обновить сломанный стол* — ватылган өстәлне төзәтү; 4. *перен.* яңарту, искә төшерү; *обновить свои знания* — үзеңнең белемнәреңне яңарту. ◇ **Обновить пальто** — яңа пальтоны беренче тапкыр кию. **Обновить путь** — юл салу (беренче тапкыр чана яки арба җигеп чыгу).

**ОБНОВИ'ТЬСЯ** *сов.* — яңару; *страна обновилась* — ил яңарды.

**ОБНО'ВКА** *ж. разг.* — к. обнова.

**ОБНОВЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. обновить.

**ОБНОВЛЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. обновиться; 2. *страд.* яңартылу; яңалык кертелү; төзәтелү; искә төшерелү.

**ОБНО'ЖКА** *ж.* — 1. *с.-х.* кәрәз ипие (бал хортлары җыеп ташый торган чәчәк тузаны); 2. *только мн. обл.* аяк йоны (сарык аягыннан, сарык башыннан кыркып алынган кыска йон).

**ОБНОСИ'ТЬ** I *сов. разг.* — 1. күнегү, ияләшү (яңа киемгә); *обносить новый костюм* — яңа костюмга күнегү; 2. туздырып бетерү; *все сапожки обносил* — итекләрен бөтенләй туздырып бетергән.

**ОБНОСИ'ТЬ** II *несов.* — к. обнести.

**ОБНОСИ'ТЬСЯ** I *сов. разг.* — 1. сәләмәләнү, бөтенләй тузып бетү; *весь обносился* — киемнәрем бөтенләй тузып бетте; 2. киелеп тәнгә яту, киеп ипләнү; *пальто ещё не обносилось и плохо сидит* — пальто әле тәнгә ятмаган, начар утыра, өскә ипсез.

**ОБНОСИ'ТЬСЯ** II *несов. страд.* — 1. таратып чыгылу (мәсәлән, кунакларга аш); 2. бирми калдырылу, буш калдырылу (мәсәлән, килгән кунакларның берәрсе).

**ОБНО'СОК** *м. чаще мн. разг.* — иске-москы (искергән кием яки искергән киемнең бер өлеше).

**ОБНЮ'ХАТЬ** *сов.* — иснәп чыгу (һәр яктан); *собака обнюхала вошедшего* — эт кергән кешене төрле яктан иснәп чыкты.

**ОБНЮ'ХАТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. иснәшү; *собаки обнюхались* — этләр иснәштеләр; 2. *простореч.* артык иснәп ...-а башлау; *обнюхаться табаком до рвоты* — артык күп тәмәке иснәп коса башлау.

**ОБНЮ'ХИВАТЬ** *несов.* — к. обнюхать.

**ОБНЮ'ХИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — к. обнюхаться.

**ОБНЯ'ТЬ** *сов.* — 1. кочаклау, кочаклап алу; *обнять ребёнка* — баланы кочаклау; 2. *перен.* каплап алу, чолгап алу; *пламя обняло весь дом* — ялкын бөтен өйне каплап алды; 3. *перен.* белү, төшенү, аңлау, башыңа сыйдыру; *обнять умом все тонкости своей науки* — үзең шөгыльләнгән фәннең бөтен нечкәлекләрен белү, аларны башыңа сыйдыру. ◇ **Обнять взглядом** — бер карауда күздән кичерү; *обнял взглядом простор полей* — бер карауда киң кырларны күздән кичерде. **Сборник обнял все его труды** — җыентыкка аның бөтен хезмәтләре кертелгән.

**ОБНЯ'ТЬСЯ** *сов.* — кочаклашу.

**ОБО** *предлог.* — к. о.

**ОБОБРА'ТЬ** *сов.* — 1. җыеп бетерү, өзеп алып бетерү; *обобрать малину в саду* — бакчадагы кура җиләген җыеп бетерү; 2. *(взять, захватить, забрать)* тартып алу; 3. *(ограбить, обокрасть, разорить)* талау, талап алу, бөлдерү.

**ОБОБРА'ТЬСЯ** *сов.* — *(только с отрицанием)* җыеп бетерә алмау; *цветов не оберёшься* — чәчәкләрне җыеп бетерә алмассың (чәчәкләр җыеп бетергесез күп). ◇ **Хлопот с ним не оберёшься** — аның белән бәладән котыла алмассың. **Я таких дел наделаю, что ты сраму и не оберёшься** — мин шундый нәрсәләр эшләрмен, син оятыңнан кая керергә белмәссең.

**ОБОБЩА'ТЬ** *несов. книж.* — к. обобщить.

**ОБОБЩА'ТЬСЯ** *несов. книж.* — 1. к. обобщиться; 2. *страд.* гомумиләштерелү, нәтиҗә чыгарылу.

**ОБОБЩЕ'НИЕ** *ср. книж.* — 1. *только ед. (действие)* к. обобщить; 2. гомуми нәтиҗә.

**ОБОБЩЕСТВИ'ТЬ** *сов.* — җәмәгатьләштерү, җәмәгать милкенә әверелдерү.

**ОБОБЩЕСТВИ'ТЬСЯ** *сов.* — җәмәгатьләшү; җәмәгать милкенә әверелү.

**ОБОБЩЕСТВЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. обобществить.

**ОБОБЩЕСТВЛЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. обобществиться; 2. *страд.* җәмәгатьләштерелү, җәмәгать милкенә әверелдерелү.

**ОБОБЩИ'ТЬ** *сов.* — гомумиләштерү, гомуми нәтиҗә чыгару.

**ОБОБЩИ'ТЬСЯ** *сов. книж.* — гомумиләшү.

**ОБОВШИ'ВЕТЬ** *сов.*— бетләп бетү.

**ОБОГАТИ'ТЕЛЬ** *м.*— 1. баетучы; 2. *спец.* казылмаларны баетучы белгеч; 3. казылмаларны баетучы матдә.

**ОБОГАТИ'ТЕЛЬНЫЙ** — казылмаларны баета торган; *обогатительная аппаратура* — казылмаларны баета торган аппаратура.

**ОБОГАТИ'ТЬ** *сов*— 1. (*сделать богатым*) баету; 2. *тех.* баету, үстерү (рудадагы, күмердәге файдасыз токымнарны чыгарып ташлап, файдалыларының процентын үстерү).

**ОБОГАТИ'ТЬСЯ** *сов.* — баю, баеп китү.

**ОБОГАЩА'ТЬ** *несов.*— к. обогатить.

**ОБОГАЩА'ТЬСЯ** *несов.*— к. обогатиться.

**ОБОГНА'ТЬ** *сов.*— узып китү.

**ОБОГНУ'ТЬ** *сов.*— 1. тарту, сугу; *обогнуть колесо шиной* — тәгәрмәчкә шин тарту; 2. (*обойти кругом*) читләтеп үтү.

**ОБОГНУ'ТЬСЯ** *сов.*— уралу.

**ОБОГОТВОРИ'ТЬ** *сов.* — аллалаштыру, алла дип тану.

**ОБОГОТВОРЯ'ТЬ** *несов.*— 1. к. обоготворить; 2. чиктән тыш олылау; алла кебек күрү, артык бирелеп ярату; *он обоготворяет свою жену* — ул үзенең хатынын алла кебек күрә, чиктән тыш ярата.

**ОБОГОТВОРЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. аллалаштырылу, алла дип танылу; 2. чиктән тыш олылану.

**ОБОГРЕВА'ТЬ** *несов. спец. разг.*— жылыту; *печи неравномерно обогревают здание* — мичләр бинаның бар җирен дә бертигез җылытмыйлар.

**ОБОГРЕВА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. обогреться; 2. *страд.* җылытылу.

**ОБОГРЕ'ТЬ** *сов.*— к. обогревать.

**ОБОГРЕ'ТЬСЯ** *сов.*— җылыну; *комната обогрелась* — бүлмә җылынды.

**О'БОД** *м.*— 1. тугым; *обод колеса* — тәгәрмәч тугымы; 2. кыса; *обод решета* — иләк кысасы.

**ОБОДНЕВА'ТЬ** *несов. обл.*— к. ободнять.

**ОБОДНЯ'ТЬ** *сов. обл.*— 1. яктырып җитү; 2. көн үткәрү.

**ОБОДО'К** *м.*— 1. кечкенә тугым (көпчәк һ. б. тугымы); 2. кайма.

**ОБОДО'ЧНЫЙ** *спец.*— тугым ...-ы; *ободочная цепь* — тугым чылбыры.

**ОБОДРА'НЕЦ** *м.*, **ОБОДРА'НКА** *ж. простореч.*— йолкыш, сәләмә киемле кеше.

**ОБОДРА'ТЬ** *сов.*— 1. каезлау, кубарып төшерү; *ободрать кору с дерева* — агачның кабыгын кубарып төшерү; 2. *разг.* өзгәләп бетерү, ертып бетерү, туздырып бетерү; *ободрать платье* — күлмәкне ертып бетерү; 3. *простореч. неодобр.* (*обобрать, разорить*) бөлдерү, талау.

**ОБОДРА'ТЬСЯ** *сов.*— 1. кубу, кубып төшү; *кора на дереве ободралась* — агачның кабыгы кубып төшкән; 2. өзелеп бетү, ертылып бетү, тузып бетү; *диван ободрался* — диван ертылып беткән; 3. (*обноситься*) тузып бетү (кием-салым).

**ОБОДРИ'ТЕЛЬНЫЙ** — рухландыра торган, дәртләндерә торган; *ободрительные слова* — рухландыра торган сүзләр.

**ОБО'ДРИТЬ** *сов.*— күңелен күтәрү, дәртләндерү, рухын күтәрү, рухландыру.

**ОБО'ДРИТЬСЯ** *сов.*— дәртләнү, күңел күтәрелү, рухлану.

**ОБОДРЯ'ТЬ** *несов.*— к. ободрить.

**ОБОДРЯ'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. ободриться; 2. *страд.* дәртләндерелү, рухландырылу.

**ОБОЕПО'ЛЫЙ** *биол.* — 1. (*о людях*) хонса, ике җенесле; 2. (*о растениях*) ике җенесле; *обоеполый цветок* — ике җенесле чәчәк.

**ОБОЕСТОРО'ННИЙ** — ике яклы, ике ягы да бертөсле; *обоесторонняя ткань* — ике ягы да бертөсле тукыма.

**ОБО'ЕЧНЫЙ** *тех.*— орлык чистарта торган; *обоечная машина* — орлык чистарта торган машина.

**ОБОЖА'НИЕ** *ср.*— 1. (*действие*) к. обожать; 2. (*сильное любовное преклонение*) чиктән тыш мәхәббәт.

**ОБОЖА'ТЕЛЬ** *м.*— сөюче, чиктән тыш яратучы кеше, артык яратучы кеше.

**ОБОЖА'ТЕЛЬНИЦА** *ж.*— к. обожатель.

**ОБОЖА'ТЬ** *несов.*— бик нык ярату, бик ярату, өзелеп сөю; *она обожала природу* — ул табигатьне бик ярата иде.

**ОБОЖА'ТЬСЯ** *несов. простореч. шутл.*— 1. бер-беренә чиктән тыш мәхәббәт тоту, яратышу, сөешү; 2. *страд.* бик нык яратылу, сөелү.

**ОБОЖДА'ТЬ** *сов.* — көтеп тору, көтә төшү; *обождать несколько минут* — берничә минут көтеп тору.

**ОБОЖЕСТВИ'ТЬ** *сов. книж.* — 1. аллалаштыру, алла дип тану; *древние обожествили силы природы* — борынгы кешеләр табигать көчләрен аллалаштырганнар; 2. *перен.* (*возвеличить, превознести*) күккә күтәрү.

**ОБОЖЕСТВЛЯ'ТЬ** *несов. книж.* — к. обожествить.

**ОБОЖЕСТВЛЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. аллалаштырылу; 2. *перен.* күккә күтәрелү, артык дәрәҗәдә мактаду.

**ОБОЖРА'ТЬ** *сов. вульг.*— к. обжирать.

**ОБОЖРА'ТЬСЯ** *сов. вульг.* — к. обжираться.

**ОБО'З** *м.*— 1. (*группа подвод*) обоз (а. олаулар төркеме; б. гаскәри частьларда транспорт средстволары; в. күчереп йөртү средстволары); 2. *перен.* авыр йөк, киртә (тарихи үсештә алга китүгә киртә булып тора торган хәл).

**ОБОЗВА'ТЬ** *сов.*— ... дип әйтү; ... дип атау; *вы меня обозвали гусаком* — сез мине ата каз дип атадыгыз.

**ОБОЗЛИ'ТЬ** *сов.* — ачуландыру, ачуын китерү.

**ОБОЗЛИ'ТЬСЯ** *сов.*—ачулану, ачуы килү.

**ОБОЗНА'ТЬСЯ** *сов. разг.*— ялгышу (таныш булмаган кешене таныш дип ялгышу, бер әйберне икенче әйбер дип уйлау).

**ОБОЗНАЧА'ТЬ** *несов.* — 1. к. обозначить; 2. (*иметь значение*) аңлату, күрсәтү, белдерү; *медленные, ровные шаги обозна-*

*чают спокойствие его души* — акрын салмак алымнар аның күңел тынычлыгын белдерә.

**ОБОЗНАЧА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. обозначиться; 2. *страд.* билгеләнү.

**ОБОЗНАЧЕ'НИЕ** *ср. книж.*—1. *только ед.* *(действие)* к. обозначить; 2. билге; *условные обозначения* — шартлы билгеләр.

**ОБОЗНА'ЧИТЬ** *сов.*— 1. билгеләү, билге кую; *обозначить тропинку на карте пунктиром* — картада сукмакны пунктир белән билгеләү; 2. белдерү, күрсәтү, күрсәтеп чыгу; *обозначу лишь самые главные обстоятельства* — тик иң мөһим хәлләрне генә күрсәтермен.

**ОБОЗНА'ЧИТЬСЯ** *сов.*— билгеләнү, күренә башлау, сизелә башлау.

**ОБО'ЗНИК** *м.*— 1. олаучы; 2. *разг.* *(военнослужащий обоза)* обозда хезмәт итүче гаскәри.

**ОБО'ЗНЫЙ** — обоз ...-ы, йөк ...-ы; *обозная лошадь* — йөк аты.

**ОБОЗРЕВА'ТЕЛЬ** *м. книж.*— 1. *(лицо, которое обозревает)* карап торучы, күзәтүче, күзәтеп торучы; 2. обзор ясаучы, обзор авторы; *военный обозреватель* — хәрби обзор ясаучы.

**ОБОЗРЕВА'ТЬ** *несов. книж.*— 1. карап тору; 2. к. обозреть.

**ОБОЗРЕВА'ТЬСЯ** *несов. страд. книж.*— 1. күзәтелү; 2. *перен.* карап тикшереп чыгылу.

**ОБОЗРЕ'НИЕ** *ср. книж.*— 1. *только ед.* *(действие)* к. обозреть, обозревать; 2. *(обзор)* күзәтү, обзор.

**ОБОЗРЕ'ТЬ** *сов. книж.*— 1. *(окинуть взором)* карап чыгу, күзәтеп чыгу; 2. *перен.* *(обследовать, рассмотреть)* карап тикшереп чыгу.

**ОБОЗРИ'МЫЙ** *книж.* — күз күрерлек, күз алымы җитәрлек.

**ОБО'ЗЧИК** *м. простореч. устар. обл.*— олаучы, йөкче.

**ОБО'И** *ед.* нет — обой, шпалер (стенага ябыштыру өчен кулланыла торган бизәкле кәгазь).

**ОБО'ЙКА** *ж.*—1. *только ед. спец.* к. обивка; 2. *тех.* *(обоечная машина)* орлык чистарту машинасы; 3. *спец.* ярма яргыч; 4. тегермәннең ярма ярдыру бүлеге; 5. *с.-х.* *(остатки льна, конопли)* талкыш, чүбек; 6. *(остатки зёрен после обмолота)* ындыр төбе, койрык.

**ОБО'ЙМА** *ж. спец.*— 1. обойма (патрон кыстыргычы); 2. *(скоба, обруч)* тимер беләзек, тимер кыршау (машинаның, корылмаларның частьларын беркетү өчен).

**ОБО'ЙНЫЙ** *спец.* — 1. обой ясау ...-ы; *обойная фабрика* — обой ясау фабрикасы; 2. тышлау ...-ы, тышлауга китә торган; *обойные материалы* — тышлауга китә торган материаллар. ◇ **Обойные гвозди** — мебель тышлаганда кулланыла торган вак кадак. **Обойная мука** *спец.* — ярдырып тарттырылган он.

**ОБОЙТИ'** *сов.*— к. обходить.

**ОБОЙТИ'СЬ** *сов.* — 1. к. обходиться; 2. *просторец.* күнегү; *лошадь обошлась в упряжке* — ат җигүгә күнекте; 3. *обл. с.-х.* буаз булу, качу; *корова обошлась* — сыер качкан. ◇ **Обойдётся** *разг. фам.*— ярый, җайланыр.

**ОБО'ЙЩИК** *м.*— обойчы, мебель тышлаучы.

**О'БОК** *нареч.* и *предлог.* с *род.* или *дат. п.*— янәшә, янында; *жить обок* — янәшә тору.

**ОБОКРА'СТЬ** *сов.*— 1. урлау, урлап чыгу, талап чыгу; *обокрали квартиру* — квартираны талап чыкканнар; 2. *разг. перен.* *(о плагиаторах)* урлау.

**ОБОЛВА'НЕТЬ** *сов. просторец.*— ахмаклану, аңгыралану.

**ОБОЛВА'НИВАТЬ** *несов. просторец.*— к. оболванить.

**ОБОЛВА'НИТЬ** *сов. просторец.*— 1. *обл. спец.* *(обтесать начерно)* юнып калып ясау, юнып болванка ясау; 2. *шутл.* *(остричь догола)* такыр итеп кыру, алдыру (чәчне); 3. *пренебр.* *(сделать болваном, глупцом)* ахмакландыру, аңгыраландыру; 4. *(одурачить, обмануть)* алдау, төпсез чуманга утырту. ◇ **Когда вас оболванишь и сделаешь похожими на людей?** *устар.*— кайчан гына сезне бераз юнгалап адәм рәтенә кертеп булыр икән?

**ОБОЛВА'НИТЬСЯ** *сов. просторец.* — 1. *(остричься наголо)* такыр итеп чәч алдыру; 2. *пренебр.* ахмаклану, аңгыралану.

**ОБОЛГА'ТЬ** *сов.*— яла ягу, өстенә сөйләү.

**ОБОЛДУ'Й** — к. обалдуй.

**О'БОЛОНЬ** *ж.*— 1. *спец.* төчлегән (агачның кайры астындагы ныгып җитмәгән яшь катлавы); 2. *обл.* каезланган колга яки бүрәнә.

**ОБОЛО'ЧКА** *ж.*— 1. җир шарын чолгап алган һава катлавы (атмосфера); 2. тышча; *оболочка пули* — пуляның тышчасы; 3. сүрү; *оболочка клетки* — күзәнәк сүрүе; 4. кабык; *оболочка зерна* — орлыкның кабыгы; 5. *перен.* кыяфәт; *это — его внешняя оболочка* — бу — аның тышкы кыяфәте. ◇ **Слизистая оболочка** — лайлалы яры. **Оболочка роговая** —мөгез катлау (күздә). **Оболочка сетчатая** —челтәр катлау (күздә).

**ОБОЛТА'ТЬ** *сов. просторец.* — чорнап алу, урап алу.

**ОБО'ЛТУС** *м. фам. бран.*— тиле, тинтәк, мәнсез, миңгерәү.

**ОБОЛЬНУ'ТЬ** *сов. разг.*— тәнгә сыланып тору, тәнгә ятып тору.

**ОБОЛЬСТИ'ТЕЛЬ** *м.* — 1. кызыктырып, соклandырып, үз ягына аударучы; 2. сокландырып юлдан яздыручы (хатын-кызны).

**ОБОЛЬСТИ'ТЕЛЬНИЦА** *ж.*— 1. к. обольститель 1; 2. матурлыгы белән сокландырып юлдан яздыручы (ирләрне).

**ОБОЛЬСТИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.*— сокландыргыч, искиткеч.

**ОБОЛЬСТИ'ТЬ** *сов.*— 1. *(прельстив, ввести в приятное заблуждение)* сокландырып үзенә ияртү, үзенә карату; 2. *устар.*

*(склонить к сожительству)* женси бәйләнешкә тарту, женси бәйләнешкә күндерү.

**ОБОЛЬСТИ'ТЬСЯ** *сов.*— кызыгып алдану.

**ОБОЛЬЩА'ТЬ** *несов.*— к. обольстить.

**ОБОЛЬЩА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. обольститься; 2. *страд.* сокландырып юлдан яздырылу; женси бәйләнешкә тартылу.

**ОБОМЛЕВА'ТЬ** *несов.*— к. обомлеть.

**ОБОМЛЕ'ТЬ** *сов. разг.*— 1. *(расслабнуть)* йомшау, әлсерәү, эреп китү, мәлҗерәү, изрәү; 2. шаккатып калу, шаккату; *обомлеть от ужаса* — куркуыннан шаккатып калу.

**ОБОМША'ЛЫЙ** — мүкләнгән, мүкләнеп беткән, мүк каплаган, мүк белән капланган; *обомшалые ели* — мүк белән капланган чыршылар.

**ОБОМША'ТЬ** *сов.*— мүкләнү, мүк үсү, мүк үсеп бетү, мүк белән каплану.

**ОБОМШЕ'ЛЫЙ** — к. обомшалый.

**ОБОМШЕ'ТЬ** *сов.*— к. обомшать.

**ОБОНЯ'НИЕ** *ср. мн.* нет — ис сизү, ис тою.

**ОБОНЯ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж. анат.*— иснәү ...-ы, ис тою ...-ы; *обонятельные нервы* — ис тою нервлары.

**ОБОНЯ'ТЬ** *несов.*— иснәү, ис тою.

**ОБОПРЕ'ТЬ** *сов. просторeч.*— пешекләнеп бетү, тирләп бетү, тиргә бату.

**ОБО'РА** *ж. обл.*— чабата киндерәсе.

**ОБОРА'ЧИВАЕМОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. *(прохождение через оборот)* оборот сәләте, оборотта булу вакыты, әйләнмәдә булу вакыты (акчаның, капиталның); 2. юлда булу (барып әйләнеп кайту) вакыты; *ускорить оборачиваемость вагонов* — вагоннарның барып кайту вакытын кыскарту.

**ОБОРА'ЧИВАТЬ** *несов.* — к. оборотить, обернуть.

**ОБОРА'ЧИВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. оборотиться; 2. *страд.* төрелү, уралу.

**ОБОРВА'НЕЦ** *м.*, **ОБОРВА'НКА** *ж. разг. презрит.*— 1. йолкыш; кылка, сәләмә киемле кеше; 2. *устар.* *(бродяга)* сукбай, зимагур.

**ОБОРВА'ТЬ** *сов.*— 1. өзү, өзеп алу; *оборвать вешалку у пальто* — пальтоның элгечен өзү; 2. өзеп алып бетерү, өзеп чыгу; *оборвать яблоки с яблони* — алмагачның алмаларын өзеп алып бетерү; 3. *перен.* кинәт туктату; бүлү, кырт кисеп туктату; *оборвать речь* — сүзне бүлү, сүзне кинәт туктату.

**ОБОРВА'ТЬСЯ** *сов.*— 1. өзелү; *конец верёвки оборвался* — бауның очы өзелгән; 2. ычкынып китеп егылып төшү; *оборваться со скалы* — кыядан ычкынып китеп егылып төшү; 3. *(внезапно прекратиться)* кинәт тукталу, бүленү, бүленеп калу; *разговор оборвался* — сүз кинәт тукталды, сүз кинәт бүленеп калды.

**ОБОРВА'ШКА** *м.* и *ж. разг. фам.*— йолкыш, сәләмә киемле кеше.

**ОБО'РВЫШ** *м. просторeч.* — к. оборвашка.

**ОБО'РИНА** *ж. обл.*— бау, тасма.

**ОБО'РКА** I *ж.*— бөрмә, бөрмәле итәк, бәби итәк.

**ОБО'РКА** II *ж. обл.*— чабата киндерәсе.

**ОБОРМО'Т** *м.*, **ОБОРМО'ТКА** *ж. просторeч.*— юньсез кеше, мәгънәсез кеше, тинтәк, хайван.

**ОБОРО'НА** *ж. мн.* нет — оборона (1. һөҗүмгә каршы тору; 2. дошман гаскәре басып керүдән илне саклау; *крепить оборону страны* — илнең оборонасын ныгыту; 3. оборона өчен кирәк булган корылмалар системасы; *прорвать оборону противника* — дошманның оборонасын өзү).

**ОБОРО'НЕЦ** *м. полит.*— обороначылык тарафдары.

**ОБОРОНИ'ТЕЛЬНЫЙ** — оборона ...-ы; *оборонительные сооружения* — оборона корылмалары.

**ОБОРОНИ'ТЬ** *сов.*—к. оборонять. ◇ **Оборони бог** *устар.*— алла сакласын.

**ОБОРОНИ'ТЬСЯ** *сов.*— к. обороняться.

**ОБОРО'ННЫЙ**—оборона ...-ы; *оборонная промышленность* — оборона промышленносте.

**ОБОРОНОСПОСО'БНОСТЬ** *ж. мн.* нет— оборона сәләте; саклау сәләте, саклану сәләте, саклануга сәләтлелек.

**ОБОРОНОСПОСО'БНЫЙ** — оборонага сәләтле.

**ОБОРО'НЧЕСКИЙ** — обороначылык ...-ы; *оборонческая тактика* — обороначылык тактикасы.

**ОБОРО'НЧЕСТВО** *ср. мн.* нет — обороначылык (II Интернационалга кергән оппортунистик партияләрнең 1914—18 еллардагы империалистик сугышта үз илләрендәге буржуазияне яклау политикасы. Бу партияләр, „ватанны саклау" лозунгысы ташлаган булып, эшчеләр сыйныфына, социализм интересларына турыдан-туры хыянәт иттеләр һәм үз илләрендәге буржуазиянең империалистик позицияләренә күчтеләр).

**ОБОРОНЯ'ТЬ** *несов.*— 1. саклау; *оборонять крепость* — крепостьны саклау; 2. *(защищать, оберегать)* яклау, җәберләргә ирек бирмәү.

**ОБОРОНЯ'ТЬСЯ** *несов.*— саклану; дошман гаскәре басып керүдән саклану; һөҗүмнән саклану, һөҗүмгә каршы тору.

**ОБОРО'Т** *м.*— 1. әйләнеш, оборот; *вал делает 20 оборотов в минуту* — вал минутка 20 оборот ясый; 2. әйләнеш; *оборот капитала* — капитал әйләнеше; 3. *фин.* оборот; *годовой оборот* — еллык оборот; 4. әйләнү; *оборот пласта при вспашке целины* — чирәм сөргәндә кәсенең бер ягыннан икенче ягына әйләнүе; 5. кире ягы, тискәре ягы; *оборот медали* — медальнең тискәре ягы; 6. *спец. устар.* борылма; *обороты реки* — елганың борылмалары; 7. буын; *в трубе пять оборотов* — биш буынлы труба; 8. юнәлеш алу; ...-ып китү; *болезнь приняла дурной оборот* — авыру начарланып китте. 9. барып кайту вакыты; *оборот вагонов* — вагоннарның барып кайту вакыты. ◇ **Оборот речи** — сүз әйләнмәсе. **Пустить в оборот** — оборотка җибәрү, эшкә җибәрү. **Взять в оборот** — бик каты шелтәләү, кирәген бирү.

**О'БОРОТЕНЬ** *м.*— убыр.

**ОБОРО'ТИСТЫЙ** *простореч.* — өлгер, житез, елдам, булдыклы, уңган: *бабёнка-то оборотиста, не оплела бы тебя на старости* (А. Островский) — уңган хатын, карт кеендә үзеңнең башыңны әйләндерә күрмәсен.

**ОБОРОТИ'ТЬ** *сов. просторе.* — к. обернуть.

**ОБОРОТИ'ТЬСЯ** *сов. просторeч.* — к. обернуться 1, 2, 3, 4, 5, 6, 7 и обратиться 1, 2.

**ОБОРО'ТЛИВОСТЬ** *ж. мн.* нет, *разг.* — өлгерлек, житезлек, булдыклылык.

**ОБОРО'ТЛИВЫЙ** *разг.* — к. оборотистый.

**ОБОРО'ТНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *тех.* — әйләнеш саны (тәгәрмәчнең, моторның һ. б.).

**ОБОРО'ТНЫЙ** — 1. тискәре ягы; *оборотная сторона листа* — битнең тискәре ягы; 2. обороттагы; *оборотные деньги* — обороттагы акчалар. ◇ **Оборотная сторона или оборотная сторона медали** *перен.* — эшнең кире ягы.

**ОБОРТОВА'ТЬСЯ** *сов. мор.* — бортка борт килеп туктау, янына килеп туктау (пароход).

**ОБОРУ'ДОВАНИЕ** *ср. мн.* нет, *тех.* — 1. *(действие)* к. оборудовать 1; 2. *(инвентарь)* оборудование, җиһаз (һәртөрле җиһазлар, төрле кораллар).

**ОБОРУ'ДОВАТЬ** *сов.* и *несов.* — 1. җиһазландыру, кирәкле нәрсәләр белән тәэмин итү; 2. *просторeч. шутл.* (*устроить, наладить*) рәтләү, җайлау; *с деньгами, говорит, можно это дело оборудовать* — акча белән бу эшне рәтләп була, ди.

**ОБОРУ'ДОВАТЬСЯ** *несов. страд.* — җиһазландырылу.

**ОБО'РЧАТЫЙ** — бөрмәләп тегелгән; бөрмәле; *оборчатый подол платья* — күлмәкнең бөрмәләп тегелгән итәге.

**ОБО'РЫШ** *м. просторeч.* — калдык-постык (сайлаганнан соң калган җимешләр турында).

**ОБОСНО'ВАННОСТЬ** *ж. мн.* нет — нигезләнгәнлек, дәлилләнгәнлек, төплелек.

**ОБОСНО'ВАННЫЙ** — дәлилләнгән, нигезләнгән, төпле.

**ОБОСНОВА'ТЬ** *сов.* — нигезләү, дәлилләү, дәлил китерү.

**ОБОСНОВА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — урнашу; *обосновался на юге* — көньякта урнашкан.

**ОБОСНО'ВЫВАТЬ** *несов. книж.* — к. обосновать.

**ОБОСНО'ВЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. *разг.* к. обосноваться; 2. *страд.* дәлил китерелү, нигезләнү, дәлилләнү.

**ОБОСО'БИТЬ** *сов. книж.* — 1. (*отделить, выделить*) аерып кую; 2. *грам.* аерымлау.

**ОБОСО'БИТЬСЯ** *сов. книж.* — 1. аерылу; 2. *грам.* аерымлану.

**ОБОСО'БЛЕННЫЙ** *книж.* — 1. үзенә башка; *обособленное положение* — үзенә башка бер хәл; 2. аерымланган; *обособленные второстепенные члены предложения* — җөмләнең аерымланган иярчен кисәкләре.

**ОБОСОБЛЯ'ТЬ** *несов. книж.* — к. обособить.

**ОБОСОБЛЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. обособиться; 2. *страд.* аерымландырылу.

**ОБОСТРЁННОСТЬ** *ж. мн.* нет — кискенләшкәнлек.

**ОБОСТРЁННЫЙ** — 1. кискенләшкән, житдиләшкән; *обострённые отношения* — кискенләшкән мөнәсәбәтләр; 2. сизгер, үткен; көчәйгән; *обострённое чувство* — көчәйгән тойгы; 3. очлайган, очлы, чыгып тора торган; *обострённые скулы* — очлайган янак сөякләре.

**ОБОСТРИ'ТЬ** *сов.* — 1. көчәйтү, үткенләштерү; *обострить внимание* — игътибарны (дикъкатьне) көчәйтү; 2. кискенләштерү; *обострить отношения* — үзара мөнәсәбәтләрне кискенләштерү.

**ОБОСТРИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. очлаю; *лицо у гармониста всё обострилось, скулы торчали двумя резкими углами* — гармоньчының йөзе бөтенләй очлаеп, янак сөякләре ике почмак төсле чыгып торалар иде; 2. *книж.* үткенләшү, көчәю; *слух обострился* — ишетү сәләте үткенләште; 3. авыраю, көчәю; *болезнь обострилась* — авыру көчәйде; 4. кискенләшү; *классовая борьба обострилась* — сыйнфый көрәш кискенләште.

**ОБОСТРЯ'ТЬ** *несов.* — к. обострить.

**ОБОСТРЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. обостриться; 2. *страд.* үткенләштерелү, көчәйтелү, кискенләштерелү.

**ОБО'ЧИНА** *ж.* — чит, кырый (1. юлның чите, кырые; 2. урман һ. б. чите, кырые); *пошёл со станции обочиной леса* — станциядән чыгып, урман чите буйлап китте.

**ОБОЮ'ДНЫЙ** — үзара, һәр ике яктан; *по обоюдному согласию* — һәр ике як риза булып, үзара килешү буенча; *обоюдная пальба* — һәр ике яктан атыш.

**ОБОЮДОВЫ'ГОДНЫЙ** — ике як өчен дә файдалы, ике якка да файдалы.

**ОБОЮДООО'СТРЫЙ** — 1. ике ягы да үткен; *обоюдоострый кинжал* — ике ягы да үткен хәнҗәр; 2. *перен.* ике яклы, ике якка юнәлдерелгән, ике як өчен дә кискен; *обоюдоострое решение* — ике як өчен дә кискен карар.

**ОБОЮДОСТОРО'ННИЙ** — үзара, ике якка да караган; *обоюдостороннее соглашение* — үзара килешү.

**ОБПА'ЧКАТЬ** *сов. просторeч.* — к. опачкать.

**ОБПИВА'ТЬ** *несов. разг.* — к. обпить.

**ОБПИ'ТЬ** *сов. разг.* — кеше хисабына эчү, кеше акчасын эчеп бетерү.

**ОБРАБА'ТЫВАЕМОСТЬ** *ж. мн.* нет, *спец.* — эшкәртелүчәнлек; *различие материалов по обрабатываемости* — материалларның эшкәртелүчәнлек ягыннан төрле-төрле булуы.

**ОБРАБА'ТЫВАТЬ** *несов.* — к. обработать.

**ОБРАБА'ТЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. обработаться; 2. *страд.* эшкәртелү.

**ОБРАБО'ТАТЬ** *сов.* — 1. эшкәртү; *обработать землю* — җирне эшкәртү; 2. эшләп

житкерү; *эту статью нужно обработать* — бу мәкаләне эшләп житкерергә кирәк; 3. *разг. фам.* (*склонить на свою сторону*) үз ягына аудару (кемне дә булса); 4. *простореч. фам.* аударып ташлау, эшләп ташлау; *обработать дельце* — эшне аударып ташлау.

**ОБРАБО'ТАТЬСЯ** *сов. разг.* — эшли торгач җайлану, җайланып китү; *инструмент обработался* — инструмент эшли торгач җайланды.

**ОБРАБО'ТКА** *ж.* — эшкәртү; эшкәртелү; эшкәртелеш, эшләнеш; *обработка земли* — җирне эшкәртү; җирнең эшкәртелеше, җирнең эшкәртелүе; *народные песни в обработке композитора* — композитор эшкәртүендә халык җырлары (композитор тарафыннан эшкәртелгән халык җырлары).

**ОБРАБО'ТЧИК** *м. спец.* — эшкәртүче; *обработчик рукописей* — кулъязмаларны эшкәртүче.

**ОБРА'ВНИВАТЬ** *несов. разг.* — к. обровнять.

**ОБРА'ВНИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. к. обровняться; 2. *страд.* тигезләнү, тигезләп чыгылу.

**ОБРА'ДОВАТЬ** *сов.* — шатландыру, сөендерү, куандыру.

**ОБРА'ДОВАТЬСЯ** *сов.* — шатлану, сөенү, куану.

**О'БРАЗ** I *м.* — 1. *книж.* сурәт, кыяфәт, рәвеш; *потерять образ человеческий* — кешелек кыяфәтен югалту; 2. күренеш; *светлые образы будущего* — киләчәкнең якты күренешләре; 3. образ; *поэт мыслит образами* — шагыйрь образлар аша фикер йөртә; 4. тип, образ (актёр яки художник тарафыннан тудырылган тип); 5. тәртип, куелыш, төзелеш; *образ правления* — идарә итү тәртибе; *образ жизни* — тормыш тәртипләре. ◇ **Надлежащим образом** — тиешле рәвештә. **Протестовать самым решительным образом** — иң кискен рәвештә каршы чыгу, протест белдерү. **Главным образом** — башлыча. **Некоторым образом** — берәр төрле юл белән. **Равным образом** — шулай ук. **Каким образом** — ничек, ни рәвештә. **Таким образом** — шулай итеп, шул рәвешчә, шул рәвештә. **Обстоятельство образа действия** *грам.* — рәвеш хәле. **По образу и подобию** — охшатып, ...төсле итеп.

**О'БРАЗ** II *м.* — к. икона.

**ОБРАЗЕ'Ц** *м.* — үрнәк, өлге, образец; *комбайн нового образца* — яңа образецтагы комбайн.

**ОБРАЗИ'НА** *ж. мн.* нет, *простореч. презрит.* — шыксыз, кыяфәтсез, ямьсез (кеше).

**ОБРАЗНА'Я** *устар. церк.* — 1. иконалар бүлмәсе (гыйбадәт кылу өчен); 2. (*иконописная мастерская*) иконалар ясау мастерское.

**О'БРАЗНОСТЬ** *ж. мн.* нет — образлылык, тасвирлылык; *речь его отличалась образностью* — аның сөйләве тасвирлылы белән аерылып тора иде.

**О'БРАЗНЫЙ** — образлы, тасвирлы; *образная речь* — образлы сөйләм; *образное выражение* — образлы әйтем.

**ОБРАЗОВА'НИЕ** I *ср.* — 1. (*действие*) к. образовать; 2. *книж.* барлыкка килгән; *жировые образования под кожей* — тире астында барлыкка килгән май катламы.

**ОБРАЗОВА'НИЕ** II *ср.* — 1. белем алу; *граждане СССР имеют право на образование* — СССР гражданнары белем алуга хокуклы; 2. белем; *высшее образование* — югары белем.

**ОБРАЗО'ВАННОСТЬ** *ж. мн.* нет — белемлелек, укымышлылык; *образованность свою хочет показать* (Чехов) — үзенең укымышлылыгын күрсәтергә тели.

**ОБРАЗО'ВАННЫЙ** — 1. барлыкка китерелгән, төзелгән, оештырылган; *возвышение, образованное природой* — табигать тарафыннан барлыкка китерелгән калкулык; 2. укымышлы, укыган, белемле; *нельзя быть образованным человеком, если не знать основ марксизма-ленинизма* — марксизм-ленинизм нигезләрен белмичә белемле кеше булу мөмкин түгел.

**ОБРАЗОВА'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.* — 1. белем арттыра торган; 2. *биол.* башлангыч; *образовательные ткани* — башлангыч тканьнар.

**ОБРАЗОВА'ТЬ** *сов.* и *несов.* — 1. (*составить, сделать, создать*) тәшкил итү, ясау, булдыру, барлыкка китерү; *за год накопления образуют крупную сумму* — ел буена җыелган акча зур сумма тәшкил итә; 2. төзү, оештыру; *образовать комиссии* — комиссияләр оештыру; 3. *устар.* укыту, аң-белем бирү, тәрбияләү; *у нас надо образовать народ* (Л. Толстой) — бездә халыкка аң-белем бирергә кирәк; 4. яхшырту, төзәтү, эшкәртү; *мало-помалу я образовал свой слог* — әкренләп мин үземнең стилемне яхшырттым.

**ОБРАЗОВА'ТЬСЯ** *сов.* и *несов.* — 1. барлыкка килү; *образовались высокие горы* — биек таулар барлыкка килгән; 2. (*организоваться*) оешу, туу, барлыкка килү; 3. *разг.* җайлану; *я думаю, всё образуется* — минемчә, барысы да җайланыр; 4. *разг.* (*получить образование*) белем алу; *он захотел образоваться* — ул белем алырга теләде.

**ОБРАЗО'ВЫВАТЬ** *несов.* — к. образовать.

**ОБРАЗО'ВЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. образоваться; 2. *страд.* ясалу, булдырылу, барлыкка китерелү, төзелү, оештырылу.

**ОБРАЗУ'МИТЬ** *сов. разг.* — акылга кертү, акылга утырту; *образумить шалуна* — шаян малайны акылга утырту.

**ОБРАЗУ'МИТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. акылга керү, акылга утыру; *теперь я образумился, но уж поздно* (Тургенев) — хәзер мин акылга утырдым, ләкин соң инде; 2. *устар.* (*опомниться, прийти в себя*) һушка килү, искә килү, айну.

**ОБРАЗУ'МЛИВАТЬ** *несов. редко* — к. образумить.

**ОБРАЗУ'МЛИВАТЬСЯ** *несов. редко* — к. образумиться.

**ОБРАЗЦО'ВЫЙ** — 1. үрнәк..., үрнәк өчен

куелган; *образцовые листы бумаги* — үрнәк өчен куелган кәгазь табаклары; 2. үрнәк булырлык; *образцовое произведение* — үрнәк булырлык әсәр.

**ОБРА'ЗЧИК** *м.* — 1. к. образец; 2. *перен. книж. (показательный пример)* характерлы мисал, үрнәк булырлык мисал.

**ОБРА'МИТЬ** *сов.* — 1. рамлау, рамга кую; *обрамить портрет* — портретны рамлау; 2. *спец.* рамнар кую; *обрамить окна* — тәрәзәләргә рамнар кую.

**ОБРАМЛЕ'НИЕ** *ср.* — 1. *(действие)* к. обрамить; 2. *книж.* рам; *портрет висел в красивом обрамлении* — портрет матур рам эчендә эленеп тора иде.

**ОБРАМЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. обрамить.

**ОБРАСТА'ТЬ** *несов.* — к. обрасти.

**ОБРАСТИ'** *сов.* — 1. каплану, басу, үсеп каплау; *берега озера обросли камышом* — күлнең ярлары камыш белән капланган; *он оброс бородой* — аны сакал баскан; *обрасти жиром* — май басу; 2. барлыкка килү; *города обросли посёлками* — шәһәрләр тирәсендә посёлоклар барлыкка килде; 3. булдыру, оештыру; *обрасти хозяйством* — хуҗалык булдыру (үзенең йорт-җирен, хуҗалыгын киңәйтү).

**ОБРА'Т** *м. с.-х.* — өстен алган сөт, сепаратор сөте, сыек сөт.

**ОБРАТИ'МОСТЬ** *ж. мн.* нет, *хим.* — кайтмалык (элекке хәленә кайта алу); *обратимость химических реакций* — химик реакцияләрнең кайтмалыгы.

**ОБРАТИ'МЫЙ** *науч.* — 1. әйләнүле, кайтма (элекке хәленә кайта торган); *обратимые реакции* — кайтма реакцияләр; 2. киресенчә аңларга мөмкин булган; *обратимое сравнение* — киресенчә аңларга мөмкин булган чагыштыру.

**ОБРАТИ'ТЬ** *сов.* — 1. бору, төбәү, юнәлдерү; *обратить орудие на неприятеля* — орудиене дошманга каршы бору; *обратить разговор к другому предмету* — сүзне икенче нәрсәгә бору; 2. *перен.* күндерү, кертү, бастыру; *обратить на путь истинный* — туры юлга бастыру; 3. әверелдерү, әйләндерү; *обратить воду в пар* — суны парга әйләндерү; 4. *книж.* куллану, тоту, файдалану; *обратить деньги на погашение долгов* — акчаны бурыч түләүгә тоту. ◇ **Обратить в бегство** — качарга мәҗбүр итү. **Обратить в шутку** — көлкегә әйләндерү. **Обратить в своих сторонников** — үз ягына аудару. **Обратить внимание** — дикъкатен җәлеп итү, игътибарын юнәлдерү.

**ОБРАТИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. *книж. (повернуться)* борылу, әйләнү; *обратиться лицом к окну* — йөз белән тәрәзәгә таба борылу; 2. *книж.* кире кайту; *оскорбление всегда может обратиться на оскорбителя* — хурлауның хурлаучыга кире кайтуы бик мөмкин; 3. *книж.* әверелү, әйләнү; *он обратился в скептика* — ул скептикка әверелде; 4. *книж.* шөгыльләнә башлау; тотыну, керешү; *обратиться к науке* — фән белән шөгыльләнә башлау; 5. мөрәҗәгать итү; *обратился по важному делу к директору* — мөһим мәсьәлә буенча директорга мөрәҗәгать итте; 6. үзләштерү; *при князе Владимире Русь обратилась в христианство* — князь Владимир заманында руслар христиан динен үзләштергәннәр. ◇ **Обратиться в бегство** — качып китү, ашыгыч рәвештә чигенә башлау. **Обратиться в слух** — йотлыгып тыңлый башлау.

**ОБРА'ТНО** *нареч.* — 1. кире, кирегә; *получить деньги обратно* — акчаны кире алу; 2. *разг.* киресенчә; *нравоучения на него действовали обратно* — үгетләүләр аңа киресенчә тәэсир итә иде. ◇ **Обратно пропорциональный** — кире пропорциональ. **Билет туда и обратно** — бару һәм кайту өчен алынган билет.

**ОБРА'ТНЫЙ** — 1. кире кайту ...-ы, кире кайта торган; *обратный путь* — кайту юлы, кире кайта торган юл; *обратный поезд* — кире кайта торган поезд; 2. тискәре; *обратная сторона материи* — материянең тискәре ягы; 3. капма-каршы; *обратный смысл* — капма-каршы мәгънә; 4. кире; *обратная сила* — кире көч; *обратная величина* — кире зурлык; *обратная дробь* — кире вакланма; *обратное отношение* — кире чагыштырма. ◇ **Обратный билет** — кире кайту билеты. **Обратное получение денег** — акчаны кире кайтарып алу.

**ОБРА'ТЬ** *сов. обл.* — к. обобрать.

**ОБРАЩА'ЕМОСТЬ** *ж. мн.* нет, *спец.* — к. обращение 2.

**ОБРАЩА'ТЬ** *несов.* — к. обратить.

**ОБРАЩА'ТЬСЯ** *несов.* — к. обратиться.

**ОБРАЩЕ'НИЕ** *ср.* — 1. *только ед. (действие)* к. обратить 2, 3 и обратиться 1, 6; 2. *экон. книж.* әйләнеш; *обращение товаров* — товарларның әйләнеше; 3. мөгамәлә; *грубое обращение с детьми* — балалар белән тупас мөгамәлә; 4. эш итү; *научиться обращению с ружьём* — мылтык белән эш итәргә өйрәнү; 5. мөрәҗәгать; *обращение к читателям* — укучыларга мөрәҗәгать итү; 6. *грам.* эндәш сүз.

**ОБРЕВИЗОВА'ТЬ** *сов.* — ревизия ясау, тикшереп чыгу.

**ОБРЕ'З** *м.* — 1. *(обрезанный край, кромка)* кисем, киселеш, киселгән урын; 2. обрез (көпшәсе кисеп кыскартылган мылтык); 3. *обл.* чапчак, кисмәк (мичкәне кисеп ясалган лакан); 4. *(нож для обрезывания книг при переплетании)* китап төпләү пычагы; 5. *(порез)* кисү ярасы. ◇ **В обрез** *разг.* — җитәр-җитмәс кенә; *денег было в обрез* — акча җитәр-җитмәс кенә иде.

**ОБРЕЗА'ЛЬЩИК** *м. спец.* — кисүче (эшче).

**ОБРЕ'ЗАНЕЦ** *м. бран. устар.* — сөннәткә утыртылган кеше.

**ОБРЕЗА'НИЕ** *ср.* — 1. *рел.* сөннәтләү, сөннәткә утырту; 2. кисү.

**ОБРЕ'ЗАТЬ** *сов.* — 1. кисү, кисеп алу, кисеп ташлау; *обрезать ногти* — тырнакларны кисү; *обрезать волосы* — чәчне кисеп ташлау; 2. кисеп кыскарту; *обрежь ножки стола на вершок* — өстәлнең аяк-

ларын бер вершокка кисеп кыскарт; 3. кисеп яралау; *обрезать палец* — бармакны кисеп яралау; 4. *разг.* сүзен бүлү, кырт кисеп туктату; *он его на первом слове обрезал* — ул беренче сүзеннән үк аны кырт кисеп туктатты; 5. *спец.* (*при кладке или рубке стены — сделать уступом*) киртләү, баскыч-баскыч итеп ясау; 6. *рел.* сөннәткә утырту. ◇ **Обрезать крылья** *перен.*— өметен өзү, канатын сындыру.

**ОБРЕЗА'ТЬ** *несов.*— к. обре́зать.

**ОБРЕ'ЗАТЬСЯ** *сов.* — 1. киселү; *обрезаться бритвой* — бритвага киселү; 2. *перен. фам.* кабу, эләгү; *я на этом деле обрезался* — мин бу эш белән каптым, минем бу эштә авызым пеште.

**ОБРЕЗА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. *разг.* к. обре́заться; 2. *страд.* кисеп ташлану, кисеп кыскартылу; кисеп алыну.

**ОБРЕ'ЗКОВЫЙ** — кисәкләрдән ясалган; *обрезковая подошва* — кисәкләрдән ясалган олтан.

**ОБРЕЗНО'Й** *спец.* — читләре киселгән; *обрезные доски* — читләре киселгән такталар.

**ОБРЕ'ЗОК** *м.*— кисенте; *колбасные обрезки* — колбаса кисентеләре. ◇ **Одеяло из обрезков** — корама юрган.

**ОБРЕ'ЗОЧНЫЙ** *спец.*— кисәк-кисәк, кисәкләрдән ясалган.

**ОБРЕ'ЗЧИК** *м. спец.*— кисүче (эшче); *обрезчик фанеры* — фанера кисүче эшче.

**ОБРЕ'ЗЫВАТЬ** *несов.*— к. обреза́ть.

**ОБРЕ'ЗЫВАТЬСЯ** *несов.*— к. обреза́ться.

**ОБРЕКА'ТЬ** *несов. книж.*— к. обречь.

**ОБРЕКА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. *устар.* к. обречься; 2. *страд.* мәҗбүр ителү, дучар ителү.

**ОБРЕМЕНИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.* — авыр, мәшәкатьле; *обременительные обязанности* — мәшәкатьле вазифалар.

**ОБРЕМЕНИ'ТЬ** *сов.*— мазасызлау, комачаулау, борчу, уңайсызлау, мәшәкатьләү; *обилие дорожных вещей обременило его* — юл әйберләренең күп булуы аны бик мәшәкатьләде.

**ОБРЕМЕНИ'ТЬСЯ** *сов.*— уңайсызлык арттыру, мәшәкать арттыру.

**ОБРЕМЕНЯ'ТЬ** *несов. книж.*— к. обременить.

**ОБРЕМЕНЯ'ТЬСЯ** *несов.* — к. обремениться.

**ОБРЕМИ'ЗИТЬ** *сов. перен. разг.*— хәйләләп алдау, күңелсез хәлгә төшерү, уңайсыз хәлгә кую.

**ОБРЕМИ'ЗИТЬСЯ** *сов. перен.*— уңайсыз хәлдә калу, күңелсез хәлгә төшү.

**ОБРЕСТИ'** *сов.* — табу, эзләп табу; *обрёл себе друга* — үзенә дус тапты.

**ОБРЕСТИ'СЬ** *сов. книж.*— табылу; *книжка обрелась под столом* — китап өстәл астыннан табылды.

**ОБРЕ'СТЬ** — к. обрести.

**ОБРЕТА'ТЬ** *несов. книж. ритор. разг. ирон.*— к. обрести.

**ОБРЕТА'ТЬСЯ** *несов. книж. устар. теперь разг. фам.*— тору, булу, яшәү; *в то время... обреталась в Москве некая вдова* — ул чагында ... Москвада ниндидер бер тол хатын яшәгән.

**ОБРЕЧЁННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— һәлакәткә дучарлык, дучар булганлык, дучар ителгәнлек, хөкем ителгәнлек.

**ОБРЕ'ЧЬ** *сов. книж.*— мәҗбүр итү, дучар итү.

**ОБРЕ'ЧЬСЯ** *сов. книж.*— мәҗбүр булу, дучар булу.

**ОБРЕШЕ'ТИНА** *ж.* — шикмә (каралты түбәсенең бәбкәсенә аркылы салына торган колгалар яки такталар).

**ОБРЕШЕ'ТИТЬ** *сов.*— 1. араталау (каралты түбәсенә колгалар яки такталар тезү); 2. челтәрләү, рәшәткәләү (стенаны штукатурлау өчен).

**ОБРЕШЕ'ЧИВАТЬ** *несов. тех.*— к. обрешетить.

**ОБРЕШЕ'ЧИВАТЬСЯ** *несов.* — рәшәткәләнү, араталану, челтәрләнү.

**ОБРИВА'ТЬ** *несов.*— к. обрить.

**ОБРИСОВА'ТЬ** *сов.*— 1. *разг.* (*обвести чертой*) тирәли сызып чыгу; 2. *перен.* сөйләп бирү, тасвирлау, тасвир итү; *оратор обрисовал современное международное положение* — оратор хәзерге халыкара хәлне сөйләп бирде.

**ОБРИСОВА'ТЬСЯ** *сов.*— 1. (*стать видимым, заметным*) күренә башлау, беленә башлау; 2. *перен.* беленү, ачыклану, мәгълүм булу; *достоинства и недостатки его характера обрисовались достаточно* — аның характерының яхшы һәм кимчелекле яклары җитәрлек дәрәҗәдә ачыкланды.

**ОБРИСО'ВЫВАТЬ** *несов.*— к. обрисовать.

**ОБРИСО'ВЫВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. обрисоваться; 2. *страд.* тирәли сызып чыгылу; 3. *страд.* тасвирлану, тасвир ителү, сөйләп бирелү.

**ОБРИ'ТЬ** *сов.*— алу, кырку, кыркып ташлау (чәчне, сакалны).

**ОБРИ'ТЬСЯ** *сов.*— башны кыру, чәчне алдыру.

**ОБРОБЕ'ЛЫЙ** *разг.*— к. оробелый.

**ОБРОБЕ'ТЬ** *сов.* — к. оробеть.

**ОБРОВНЯ'ТЬ** *сов. разг.*— тигезләү, тигезләп чыгу; *обровнять края материи* — материянең читләрен тигезләп чыгу.

**ОБРОВНЯ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— тигезләнү (чите, өсте).

**ОБРО'К** *м. истор.*— оброк, салым (алпавытлар тарафыннан крестьяннарга салынган салым).

**ОБРОНИ'ТЬ** *сов. разг.*— югалту, җую, төшереп калдыру; *обронить в трамвае деньги* — трамвайда акчаны төшереп калдыру.

**ОБРОТА'ТЬ** *сов. обл.*— нукталау, нукта кертү (атка).

**О'БРОТЬ** *ж. обл.*— нукта.

**ОБРО'ЧНИК** *м. истор.*— оброк түләүче крестьян, салым түләүче крестьян.

**ОБРО'ЧНЫЙ** *истор.*— 1. оброк түләүче; *оброчные крестьяне* — оброк түләүче крестьяннар; 2. оброктан җыелган, оброктан килгән; *оброчные деньги* — оброктан килгән акчалар; *оброчные доходы* — об-

роктан килгән доходлар; 3. арендага бирелә торган; *оброчные угодья* — арендага бирелә торган җирләр.

**ОБРУ'Б** *м.* — 1. *только ед.* к. обрубка; 2. *(бревенчатый сруб)* бура (кое, баз һ. б. өчен); 3. *(место, где обрублено топором)* балта чапкан урын, балта белән киселгән урын.

**ОБРУБА'ТЬ** *несов.* — к. обрубить.

**ОБРУБА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — тирәли киселү, кисеп алыну.

**ОБРУБИ'ТЬ** *сов.* — 1. кисү, кисеп ташлау, кисеп алу; *обрубить сучья* — агач ботакларын кисеп ташлау; 2. *порт.* каю, читен бөгү, читен бөгеп чыгу, теген чыгу; *она взяла обрубить твои платки* — ул кулъяулыкларыңның читен бөгеп чыгарга алды.

**ОБРУ'БКА** *ж. мн.* нет — к. обрубить.

**ОБРУ'БОК** *м.* — бүкән, тумран, кисәк.

**ОБРУГА'ТЬ** *сов.* — орышу, тиргәү, тиргәп ташлау, сүгү, сүгеп ташлау.

**ОБРУСЕ'ЛЫЙ** — руслашкан; *обруселый поляк* — руслашкан поляк.

**ОБРУСЕ'ТЬ** *сов.* — руслашу.

**ОБРУСИ'ТЕЛЬ** *м. книж.* — руслаштыручы (патша Россиясендә руслаштыру политикасын үткәрүче).

**ОБРУСИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.* — руслаштыру ...-ы; *обрусительная политика царского правительства* — патша хөкүмәтенең руслаштыру политикасы.

**ОБРУСИ'ТЬ** *сов.* — руслаштыру (патша Россиясендә төрле юллар белән көчләп рус телен, рус гадәтләрен үзләштерүгә мәҗбүр итү, милли культураларның үсешенә юл куймау).

**О'БРУЧ** *м.* — коршау.

**ОБРУЧА'ЛЬНЫЙ**: обручальное кольцо — никах балдагы (ярәшү билгесе итеп киелә торган балдак); обручальный обряд — ярәшү йоласы, никах йоласы.

**ОБРУЧА'ТЬ** *несов.* — никахландыру.

**ОБРУЧА'ТЬСЯ** *несов.* — никахлану.

**ОБРУЧИ'ТЬ** *сов.* — к. обручать.

**ОБРУЧИ'ТЬСЯ** *сов.* — к. обручаться.

**ОБРУ'ЧНЫЙ** *спец.* — 1. коршау ...-ы; *обручное производство* — коршау производствосы; 2. коршаулык...; *обручное железо* — коршаулык тимер.

**ОБРУ'ЧЬЕ** *ср. устар.* — беләзек сөяге.

**ОБРУША'ТЬ** *несов. устар.* — к. обрушивать.

**ОБЫГРА'ТЬ** *сов.* — 1. (*выиграть*) оту, отып бетерү; 2. *муз. арго* (*улучшить посредством игры*) уйнап тавышын яхшырту (музыка коралларының); 3. *театр. арго* (*использовать для сценической игры*) уйнарга җайлау (театр обстановкасын); 4. *разг. фам.* файдалану, үз файдасына куллану; *обыграть ошибку противника в споре* — каршы якның бәхәстә булган хаталарыннан файдалану.

**ОБЫ'ГРЫВАТЬ** *несов.* — к. обыграть.

**ОБЫ'ГРЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. отылу; 2. уйнап тавышы яхшыртылу, уйнарга җайланылу.

**ОБЫДЁНКОЙ** *нареч. просторечь.* — бер көн эчендә; *покончить обыдёнкой все дела* — бер көн эчендә бөтен эшләрне бетерү.

**ОБЫ'ДЕННОСТЬ** и **ОБЫДЁННОСТЬ** *ж. книж.* — 1. *только ед.* гадилек; *обыденность суждений* — фикер йөртүләренең гадилеге; 2. көн саен була торган вакыйга, көн дә очрый торган вакыйга; *обыденности жизни* — тормышта көн дә очрый торган вакыйгалар.

**ОБЫ'ДЕННЫЙ** и *устар.* **ОБЫДЁННЫЙ** — көндәлек, гадәттәге, көн дә була торган, көн дә очрый торган; *обыденное происшествие* — көн дә очрый торган вакыйга.

**ОБЫДЁНЩИНА** *ж. мн.* нет, *собир. презрит.* — көн саен кабатлана торган нәрсә.

**ОБЫКА'ТЬ** *несов. обл.* — к. обыкнуть.

**ОБЫКНОВЕ'НИЕ** *ср. книж.* — гадәт; *он имеет обыкновение опаздывать* — аның соңга кала торган гадәте бар. ◇ **По обыкновению** — гадәттәгечә. **Против обыкновения** — гадәттән тыш буларак.

**ОБЫКНОВЕ'ННО** *нареч.* — 1. гадәттә; 2. к. обыкновенный 2.

**ОБЫКНОВЕ'ННЫЙ** — 1. гадәттәге, көндәлек; *приступил к обыкновенным своим занятиям* — үзенең көндәлек эшләренә кереште; 2. (*заурядный*) гади, уртача.

**ОБЫ'КНУТЬ** *сов. обл.* — күнегү, күнегеп җитү, күнегеп бетү, күнегеп китү.

**О'БЫСК** *м.* — 1. тентү; 2. *устар. церк.* (*опрос*) тикшерү (өйләнешә торган кыз белән егетнең үзара туган-тугандаш булу-булмауларын сорашып тикшерү).

**ОБЫСКА'ТЬ** *сов.* — тентү, тентеп чыгу; бар җирне эзләп чыгу, эзләп актарып чыгу.

**ОБЫСКА'ТЬСЯ** *сов. просторeч. фам.* — эзләп чыгу; бик озак эзләү; *обыскался, но нигде ничего не нашёл* — бик озак эзләдем, ләкин бернәрсә дә тапмадым.

**ОБЫ'СКИВАТЬ** *несов.* — к. обыскать.

**ОБЫ'СКИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — тентелү, тентеп чыгылу.

**ОБЫСКНО'Й** *офиц. устар.* — тентү...-ы; *обыскной ордер* — тентү ордеры.

**ОБЫ'ЧАЙ** *м.* — йола, гореф-гадәт; *свадебные обычаи* — туй йолалары. ◇ **В обычае** *кого-н. разг.* — гадәтенә кергән; *работать по ночам в его обычае* — төнлә эшләү аның гадәтенә кергән.

**ОБЫ'ЧНО** *нареч.* — гадәттә.

**ОБЫ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет — гадәттәгелек, көндәлек.

**ОБЫ'ЧНЫЙ** — гадәттәге; *он сидел на своем обычном месте* — ул үзенең гадәттәге урынында утыра иде.

**ОБЮРОКРА'ТИТЬ** *сов. разг.* — бюрократлаштыру.

**ОБЮРОКРА'ТИТЬСЯ** *сов. разг.* — бюрократлашу.

**ОБЯ'ЗАННОСТЬ** *ж. книж.* — бурыч, вазифа, йөкләмә, хезмәт; *права и обязанности граждан* — гражданнарның хокуклары һәм бурычлары; *взять на себя обязанность известить родных* — туганнарга хәбәр итү бурычын үз өстенә алу.

**ОБЯЗА'ТЕЛЬНО** *нареч.* — 1. әлбәттә, мәҗбүри, һичшиксез; *сегодня он обязательно придёт* — ул бүген әлбәттә (һичшиксез) килер; 2. *устар. нареч.* к. обязательный 2.

**ОБЯЗА'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — мәҗбүрилек.

**ОБЯЗА'ТЕЛЬНЫЙ** — 1. мәҗбүри, мәҗбүр итә торган, ирексез, йөкләнгән, бурыч ителгән; *в обязательном порядке* — мәҗбүри рәвештә; 2. *устар.* һәрвакыт ярдәм итәргә хәзер.

**ОБЯЗА'ТЕЛЬСТВЕННЫЙ** *право* — йөкләмә...-ы; өскә алган бурыч...-ы; мәҗбүр итү...-ы; *обязательственное право* — мәҗбүр итү хокукы.

**ОБЯЗА'ТЕЛЬСТВО** *ср.* — 1. йөкләмә, йөкләнмә, вазифа, өскә алынган бурыч, вәгъдә; 2. *спец.* облигациянең бер төре.

**ОБЯЗА'ТЬ** *сов.* — йөкләү, мәҗбүр итү. ◇ **Вы меня очень обяжете** — мин үземне сезнең каршыда бурычлы дип санар идем.

**ОБЯЗА'ТЬСЯ** *сов.* — өскә алу, вәгъдә бирү.

**ОБЯ'ЗЫВАТЬ** *несов.* — к. обязать.

**ОБЯ'ЗЫВАТЬСЯ** *несов. офиц.* — 1. к. обязаться; 2. *разг.* бурычлы булу; *не хочу я перед ним обязываться* — минем аңа бурычлы буласым килми; 3. *страд. редко* йөкләнү, мәҗбүр ителү.

**ОВА'Л** *м.* — овал, озынча түгәрәк.

**ОВА'ЛЬНЫЙ** — озынча түгәрәк...; *овальная рама* — озынча түгәрәк рам.

**ОВА'МО**: **семо и овамо** *устар.* — монда да тегендә дә; уңга да сулга да.

**ОВА'ЦИЯ** *ж. книж.* — алкышлау, алкыш, көчле кул чабулар (җыелышларда).

**ОВДОВЕ'ТЬ** *сов.* — тол калу, тол булып калу.

**ОВЕВА'ТЬ** *несов. книж. поэт.* — җилләндереп тору, исеп тору.

**ОВЕ'ИВАТЬ** *несов. книж.* — к. овевать.

**ОВЁС** *м.* — солы.

**ОВЕ'ЧИЙ** — сарык...-ы; *овечья шерсть* — сарык йоны.

**ОВЕ'ЧКА** *ж.* — 1. *разг.* кечкенә сарык; 2. *перен. шутл. ирон.* юаш кеше; *прикинуться овечкой* — юаш булып күренергә тырышу, юашка салыну.

**ОВЕЩЕСТВИ'ТЬ** *сов. книж.* — матдиләштерү, матди (материаль) хәлгә китерү.

**ОВЕЩЕСТВИ'ТЬСЯ** *сов. книж.* — матдиләшү, матди хәлгә килү.

**ОВЕ'ЯТЬ** *сов. книж. поэт.* — к. овеять 1. ◇ **Советские знамена овеяны славой** — Совет байраклары данга күмелгән.

**ОВИВА'ТЬ** *несов. книж. поэт.* — к. овить.

**ОВИВА'ТЬСЯ** *несов. книж. поэт.* — к. овиться.

**ОВИ'Н** *м. с.-х.* — әвен (көлтә киптерү урыны).

**ОВИ'ННЫЙ** *с.-х.* — әвен...-ы; *овинный хлеб* — әвен ашлыгы.

**ОВИ'ТЬ** *с.-х. книж. поэт.* — к. обвить.

**ОВИ'ТЬСЯ** *сов. книж. поэт.* — к. обвиться.

**ОВЛАДЕВА'ТЬ** *несов. книж.* — к. овладеть.

**ОВЛАДЕ'ТЬ** *сов. книж.* — 1. (*захватить*) алу; кулга алу, кулга төшерү; 2. буйсындыру; *овладеть чьими-нибудь мыслями, поступками* — кемнең дә булса фикерләрен (уйларын), эшләрен үзенә буйсындыру; 3. *перен.* басу, чолгап алу; *мною овладел страх* — мине курку басты; 4. *перен.* үзләштерү, өйрәнү, ия булу; *овладеть техникой* — техниканы үзләштерү. ◇ **Овладеть собой** — үзеңне кулга алу. **Мною ов-**

задела радость— мин бик куандым, мин бик шатландым.

**О'ВОД** *м.* — кигәвен.

**ОВОЩЕВО'Д** *м.* — яшелчә үстерүче белгеч, яшелчәче.

**ОВОЩЕВО'ДСТВО** *ср. мн.* нет, *с.-х.* — яшелчәчелек, яшелчә үстерүчелек.

**ОВОЩЕХРАНИ'ЛИЩЕ** *ср. с.-х.* — яшелчәләр саклау урыны (өй, баз һ. б.).

**О'ВОЩИ** *ед. редко,* **О'ВОЩЬ** и *ж. обл.* **ОВОЩ** *м.* — яшелчә.

**ОВОЩНИ'К** *м. разг.* — яшелчә сатучы.

**ОВОЩНО'Й** — 1. яшелчә...-ы; *овощная торговля* — яшелчә сәүдәсе; 2. *в знач. сущ. разг. ж.* яшелчә кибете.

**ОВРА'Г** *м.* — чокыр, коры елга, ерым.

**ОВРА'ЖЕК** I *м.* — йомран (җәнлек).

**ОВРА'ЖЕК** II *м. уменьш.*— к. овраг.

**ОВРА'ЖИСТЫЙ** — ерганаклы, чокырлы, чокырлы-чакырлы; *овражистая местность* — ерганаклы урын.

**ОВРА'ЖНЫЙ** *спец.*—ерганак...-ы; *овражный песок* — ерганак комы.

**ОВСИ'НКА** *ж. разг.* — солы бөртеге; солы сабагы.

**ОВСЮ'Г** *м. бот.* — кара солы, солыча (чүп үлән).

**ОВСЯ'НИК** *м. обл.* — солы аюы (кырлардагы солыны ашый торган аю).

**ОВСЯ'НИЦА** *ж. мн.* нет, *бот. с.-х.* — солыбаш (азык үлән).

**ОВСЯ'НКА** I *ж. мн.* нет, *разг.* — 1. (*овсяная крупа*) солы ярмасы; 2. (*овсяная каша*) солы боткасы.

**ОВСЯ'НКА** II *ж. зоол.* — солы чыпчыгы.

**ОВСЯНО'Й, ОВСЯ'НЫЙ**— солы...-ы; *овсяное поле* — солы басуы; *овсяная каша* — солы боткасы.

**ОВЦА'** *ж.* — сарык. ◇ **Заблудшая овца** *ритор.* — юлдан язган кеше, бозылган кеше.

**ОВЦЕБЫ'К** *м. зоол.* — сарык-үгез.

**ОВЦЕВО'Д** *м.* — сарык үрчетүче специалист.

**ОВЦЕВО'ДСТВО** *ср. мн.* нет, *с.-х.* — сарык асраучылык.

**ОВЦЕВО'ДЧЕСКИЙ** *с.-х.*—сарык асраучылык...-ы; сарык...-ы; *овцеводческий район*— сарык асраучылык районы; *овцеводческая ферма* — сарык фермасы.

**ОВЦЕМА'ТКА** *ж.* — үрчем бирә торган сарык.

**ОВЧА'Р** *м.* — сарык караучы, сарык көтүчесе.

**ОВЧА'РКА** *ж.* — овчарка (эт токымы).

**ОВЧА'РНЯ** *ж.* — сарык абзары.

**ОВЧИ'НА** *ж.* — иләнгән сарык тиресе.

**ОВЧИ'НКА** *ж. спец. уменьш.*— к. овчина. ◇**Овчинка выделки не стоит** — биш тиенлек куян — ун тиенлек зыян. **Небо с овчинку показалось** — котым очты, йөрәгем ярыла язды (куркудан, авыртудан).

**ОВЧИ'ННЫЙ** — сарык тиресеннән тегелгән; *овчинный тулуп* — сарык тиресеннән тегелгән толып, бәрән толып.

**ОВШИ'ВЕТЬ** *сов.* — бетләп бетү, бет басу.

**ОГА'РОК** *м.* — 1. шәм төпчеге; 2. *простореч. презрит. бран.* (*подросток-хулиган*) тәрбиясез малай, хулиган малай.

**ОГИБА'ТЬ** *несов. простореч.*— 1. к. обогнуть; 2. әйләнеп үтү, уратып үтү; *дорога огибает гору* — юл тауны уратып үтә.

**ОГИБА'ТЬСЯ** *несов. простореч.*— 1. к. обогнуться; 2. *страд.* уратып үтелү, әйләнеп үтелү.

**ОГЛАВЛЕ'НИЕ** *ср. книж.* — эчтәлек (китаптагы бүлекләр исемлеге.)

**ОГЛА'ДИТЬ** *сов. спец. спорт.*— сыйпау (атны тынычландыру өчен).

**ОГЛА'ДЫВАТЬ** *несов. простореч.* — к. оглодать.

**ОГЛА'ЖИВАТЬ** *несов. спорт. спец.*— к. огладить.

**ОГЛА'ЖИВАТЬСЯ** *несов. спорт. спец. страд.*— сыйпалу.

**ОГЛАСИ'ТЬ** *сов. книж.*— 1. *офиц.* халыкка белдерү, игълан итү, укып чыгу; *секретарь огласил резолюцию* — секретарь резолюцияне укып чыкты; 2. *устар.* фаш итү, ачу; *огласить чужую тайну* — кешенең серен ачу; 3. яңгырату; *восторженный крик огласил тёмную комнату* — шатлыклы тавыш караңгы бүлмәне яңгыратты.

**ОГЛАСИ'ТЬСЯ** *сов. книж.* — 1. яңгырау, яңгырап китү; *зала огласилась рукоплесканиями* — зал кул чабулардан яңгырап китте; 2. *устар.* ачылу, фаш ителү; *тайна огласилась* — сер ачылды.

**ОГЛА'СКА** *ж. мн.* нет, *разг.* — фаш ителү, билгеле булу.

**ОГЛАША'ТЬ** *несов. книж.* — к. огласить.

**ОГЛАША'ТЬСЯ** *несов. книж.*—1. к. огласиться; 2. *страд.* белдерелү, игълан ителү, укып чыгылу.

**ОГЛАШЕ'ННЫЙ** *простореч. неодобр.* — юньсез, мәнсез; *он какой-то оглашенный* — ул әллә нинди юньсез.

**ОГЛО'БЛЯ** *ж.* — тәртә. ◇ **Повернуть оглобли** *разг. шутл. ирон.* — тәртә бору, буш кул белән китү (теләгенә ирешмичә кайтып китү).

**ОГЛОДА'ТЬ** *сов.*— к. обглодать.

**ОГЛО'ДОК** *м. простореч.*— к. обглодок.

**ОГЛОУ'ШИТЬ** *сов. простореч.* — колак төбенә тондыру, колак төбенә утырту.

**ОГЛО'ХНУТЬ** *сов.*— чукраклану, саңгыраулану.

**ОГЛУПЕ'ТЬ** *сов. простореч.*— аңгыралану, аңгыраланып калу, мингерәүләнү.

**ОГЛУПЛЯ'ТЬ** *несов. неодобр.* — 1. юләр итеп күрсәтү, алдарга маташу, аңгыраландыру; 2. юри бозып күрсәтү.

**ОГЛУША'ТЬ** *несов.*— 1. колак тондыру; 2. сугып һуштан яздыру.

**ОГЛУШИ'ТЕЛЬНЫЙ** — колак тондыргыч, колак тондыра торган, колак тондырырлык, бик каты; *раздался оглушительный крик*—колак тондырырлык тавыш ишетелде, бик каты тавыш ишетелде.

**ОГЛУШИ'ТЬ** *сов.* — к. оглушать.

**ОГЛЯДЕ'ТЬ** *сов.* — карап чыгу, күз йөр-

теп чыгу; *оглядеть с ног до головы* — баштанаяк күз йөртеп чыгу.

**ОГЛЯДЕ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. тирә-юньне карап алу; як-якка карану; 2. күз өйрәнү, күз күнегү; *оглядеться в темноте* — караңгыга күз өйрәнү; 3. *перен.* күнегү, күнегеп житү; *я ещё не успел оглядеться на новой работе* — мин әле яңа эшкә күнегеп житмәдем.

**ОГЛЯ'ДКА** *ж. мн.* нет, *разг.* — 1. саклык; *в этом деле нужна оглядка* — бу эштә саклык кирәк; 2. *устар.* (*запоздалое сожаление*) үкенеч, соңыннан үкенү. ◇ **Без оглядки** *разг.* — артына борылып карамыйча, алдын-артын карамый; *я без оглядки ничего не сделаю* — алдын-артын карамыйча мин бернәрсә дә эшләмәм.

**ОГЛЯ'ДЫВАТЬ** *несов.* — к. оглядеть и оглянуть.

**ОГЛЯ'ДЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. оглядеться; 2. *перен.* (*поступать осторожно*) сак булу; карап кына эш итү.

**ОГЛЯНУ'ТЬ** *сов. простореч.* — күз төшереп алу, карап алу.

**ОГЛЯНУ'ТЬСЯ** *сов.* — артка борылып карау. ◇ **Не успел оглянуться** *разг.* — күз ачып йомганчы.

**ОГНЕВИ'К** *м. обл.* — 1. (*кремень*) чакма ташы; 2. (*болячка*) шеш, чуан, сызлавык.

**ОГНЕВИ'ЦА** *ж. обл.* — 1. (*лихорадка*) бизгәк; 2. (*сыпь на губах*) иреннәр чабыру, чабыртлы.

**ОГНЁВКА** *ж. зоол.* — утчыл (күбәләк).

**ОГНЕВО'Й** — ут...-ы; *огневая завеса* — ут киртәсе. ◇ **Огневая позиция** *воен.* — ут позициясе. **Огневые очи** *перен.* — утлы күзләр. **Огневой характер** — кызу канлы, кызу характер. **Огневые речи** — ялкынлы сүзләр.

**ОГНЕДЫ'ШАЩИЙ** *книж. устар.* — ут бөрки торган, ут ыжгырып тора торган. ◇ **Огнедышащая гора** — янар тау.

**ОГНЕМЁТ** *м. воен.* — огнемёт, утаткыч (яндыргыч сыекча бөрки торган сугыш коралы).

**ОГНЕМЕТА'НИЕ** *ср. мн.* нет, *воен.* — ут сиптерү (яна торган сыекчаны огнемёттан сиптерү).

**О'ГНЕННЫЙ** *книж.* — 1. ут...-ы; *огненные языки* — ялкын телләре; 2. *перен. поэт.* ялкынлы; *огненный взор* — ялкынлы караш; 3. *старин.* к. огнестрельный.

**ОГНЕОПА'СНЫЙ** *спец.* — янгыннан хәтәрле, уттан куркынычлы, ут тиз каба торган; *огнеопасные вещества* — ут тиз каба торган матдәләр.

**ОГНЕПОКЛО'ННИК** *м.* — утка табынучы кеше.

**ОГНЕПОКЛО'ННИЧЕСТВО, ОГНЕПОКЛО'НСТВО** *ср. мн.* нет — утка табыну (примитив халыкларда).

**ОГНЕПРИПА'СЫ** *ед.* нет, *воен.* — ату кирәк-яраклары (снарядлар, бомбалар һ. б.).

**ОГНЕСТО'ЙКОСТЬ** *ж. мн.* нет, *спец.* — утка чыдамлылык, янмаучылык.

**ОГНЕСТО'ЙКИЙ** *спец.* — утка чыдам(лы), янмый торган; *огнестойкие постройки* — утка чыдам(лы) корылмалар, каралтылар.

**ОГНЕСТРЕ'ЛЬНЫЙ** *воен.* — ату...-ы, ата торган; *огнестрельное оружие* — ату коралы, ата торган корал. ◇ **Огнестрельная рана** — пуля ярасы, осколок ярасы.

**ОГНЕТУШИ'ТЕЛЬ** *м. тех.* — ут сүндергеч (прибор).

**ОГНЕУПО'РНЫЙ** *тех.* — утка түземле, утка чыдам(лы), янмый торган; *огнеупорный кирпич* — утка чыдамлы кирпеч.

**ОГНЕУПО'РЫ** *ед.* нет, *тех.* — утка чыдам(лы) материаллар, янмый торган материаллар.

**ОГНЕЦВЕ'Т** *м. бот. обл.* — миләүшәсыман кырмавык.

**ОГНИ'ВО** *ср.* — чакма, чакма ташы.

**ОГНИЩА'НИН** *м. истор.* — гаскәр башлыгы, феодалның якын киңәшчесе (рус феодализмының башлангыч дәверендә).

**ОГНИ'ЩЕ** *ср.* — 1. *простореч.* зур ут; 2. *обл.* костёр урыны; 3. *с.-х. обл.* янык (примитив игенчелек дәверендә урманны төпләгәннән яки яндырганнан соң серү өчен билгеләнгән урын); 4. *истор. собир.* бер хуҗаның барлык коллары (борынгы Русьта).

**ОГО'** *межд. разг.* — әй, әһә; *ого! Пора! вставай!* — әһә! Вакыт житте! тор!

**ОГОВА'РИВАТЬ** *несов.* — к. оговорить.

**ОГОВА'РИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. оговориться; 2. *страд.* яла ягылу; алдан әйтелеп куелу.

**ОГОВОРИ'ТЬ** *сов.* — 1. (*оклеветать*) кеше өстенә сөйләү; яла ягу; 2. (*заранее условиться*) алдан килешү, алдан сөйләшеп кую; 3. (*сделать оговорку*) төзәтмә кертү, өстәмә кертү; искәрмә ясау.

**ОГОВОРИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. (*предупредить*) искәртеп китү, әйтеп китү; 2. (*ошибиться в речи*) ялгыш әйтү, ялгыш әйтеп кую, сүздә ялгышу, сөйләүдә ялгышу.

**ОГОВО'РКА** *ж.* — 1. (*поправка, дополнение*) төзәтмә, өстәмә; 2. (*ошибка в словах*) хата әйтелгән сүз, сүз хатасы.

**ОГОВО'РЩИК** *м. разг.* — кеше өстенә сөйләүче, яла ягучы.

**ОГОЛЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — 1. ялангачлану, ялангач калу, шәрәләнү; *оголение лесов* — урманнарның ялангачлануы (агачларның яфрагы коелу); 2. төксезләнү.

**ОГОЛЁННЫЙ** — 1. ялангачландырылган; 2. *перен.* яфраксыз; *оголённые деревья* — яфраксыз агачлар.

**ОГОЛЕ'ТЬ** *сов. разг.* — 1. ялангачлану, ялангач калу; төксезләнү, шәрәләнү; 2. *перен.* ярлылану, фәкыйрьләнү.

**ОГОЛЕ'Ц** *м. простореч. бран.* — шаян малай, шук малай.

**ОГОЛИ'ТЬ** *сов.* — 1. ялангачландыру; ачу; *оголить грудь* — күкрәкне ачу; 2. *перен.* яфракларын кою, ялангачландыру; *ветер оголил деревья* — җил агачларның яфракларын койган, җил агачларны ялангачландырган; 3. *перен. воен.* саксыз калдыру, ачык калдыру; *оголить фланг* — флангны ачык калдыру.

**ОГОЛИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. ялангачлану;

шәрәләнү; 2. *перен.* яфраклары коелу; *деревья оголились* — агачларның яфраклары коелган; 3. *перен. воен.* саксыз калу, ачык калу; *фланг оголился* — фланг ачык калды.

**ОГОЛО'ВЬЕ** *ср. спец.* — йөгән (атланып йөри торган ат өчен).

**ОГОЛОДА'ТЬ** *сов. простореч.* — ачыгып йончу, ачыгып ябыгу.

**ОГОЛТЕ'ЛЫЙ** *просторечс. неодобр.* — оятсызланган, котырынган, шашынган; *оголтелый фашист* — котырынган фашист.

**ОГОЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. оголить.

**ОГОЛЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. оголиться; 2. *страд.* ялангачландырылу; 3. *страд.* саксыз калдырылу, ачык калдырылу.

**ОГОНЁК** *м.* — 1. кечкенә ут; 2. *перен.* чаткы; *юноша с артистическим огоньком* — артистлык чаткысы булган яшүсмер. ◇ Блуждающий огонёк — убыр уты (сазлыкларда, каберлекләрдә чери торган әйберләрдән чыгып үзеннән-үзе яна торган газ). На огонёк *разг. фам.* — үтеп барышлый тәрәзәдән ут күреп; *зайти на огонёк* — үтеп барышлый тәрәзәдән ут күреп керү.

**ОГО'НЬ** *м.* — 1. *только ед.* ут; 2. янгын; *страхование от огня* — янгыннан страховать итү; 3. *воен. только ед.* ут; *открыть огонь* — ут ачу. ◇ Девушка-огонь — ут кебек кыз, бик уңган кыз (булдыклы кыз, житез кыз). Антонов огонь *мед. устар.* — гангрена (тере организмның бер кисәге үлек хәлгә килүе). Между двух огней — ике ут арасында (ике куркыныч уртасында). Нет дыма без огня — утсыз төтен булмый; жилсез кура селкенми. Из огня да в полымя — бер уттан икенче утка (бер бәладән икенче бәлагә очрау). Днём с огнём не найдёшь *разг.* — көндез чыра яндырып эзләсәң дә таба алмассың. Бояться как огня — уттан курыккан кебек курку. Бежать, как от огня — уттан качкан кебек качу. Лить масло в огонь — утка керосин сибү; эт оясына таяк тыгу. Покорить огнём и мечом — ут һәм кылыч белән буйсындыру.

**ОГОРА'ЖИВАТЬ** *несов.* — киртәләү, киртә тоту (читән, койма, чокыр һ. б. белән әйләндереп алу).

**ОГОРА'ЖИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. огородиться; 2. *страд.* киртәләнү, киртә тотылу, (читән, койма, киртә һ. б. белән) әйләндереп алыну.

**ОГОРА'ШИВАТЬ** *несов. просторечс.* — к. огорошивать.

**ОГОРО'Д** *м.* — яшелчә бакчасы. ◇ Огород городить — к. городить.

**ОГОРО'ДИНА** *ж. мн.* нет, *просторечс. обл.* — яшелчәләр (яшелчә бакчасында үсә торган үсемлекләр).

**ОГОРОДИ'ТЬ** *сов.* — к. огораживать.

**ОГОРОДИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. киртәләнү, киртә, читән, койма белән бүленү; 2. *перен. неодобр. ритор.* (*стать в стороне*) читтә калу, катнашмау.

**ОГОРО'ДНИК** *м.* — 1. (*владелец огорода*) яшелчә бакчасы хуҗасы; 2. (*лицо, занимающееся огородничеством*) яшелчәләр үстерүче, яшелчәләр үстерү белән шөгыльләнүче.

**ОГОРО'ДНИЧЕСТВО** *ср. мн.* нет, *с.-х.* — яшелчә бакчачылыгы, яшелчә үстерүчелек.

**ОГОРО'ДНЫЙ** *с.-х.* — яшелчә бакчасы...ы; *огородные работы* — яшелчә бакчасы эшләре.

**ОГОРО'ШИВАТЬ** *несов. разг.* — к. огорошить.

**ОГОРО'ШИТЬ** *сов. разг.* — аптыраштa калдыру; *это известие всех нас огорошило* — бу хәбәр безнең барыбызны да аптыраштa калдырды.

**ОГОРЧА'ТЬ** *несов.* — кәеф китәрү, кәеф бозу, ачындыру; *меня огорчило это известие* — бу хәбәр минем кәефне бозды.

**ОГОРЧА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. огорчиться; 2. *страд.* кәеф китәрелү.

**ОГОРЧЕ'НИЕ** *ср.* — кәеф киту, кәеф бозылу, кәеф кырылу, күңелсезлек; кайгы, хәсрәт.

**ОГОРЧИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.* — күңелсез, кайгылы; *огорчительное известие* — күңелсез хәбәр, кайгылы хәбәр.

**ОГОРЧИ'ТЬ** *сов.* — к. огорчать.

**ОГОРЧИ'ТЬСЯ** *сов.* — кәеф киту, кәеф бозылу, кәеф кырылу, ачыну.

**ОГРА'БИТЬ** *сов.* — талау, талап алу.

**ОГРАБЛЯ'ТЬ** *несов. просторечс.* — к. ограбить.

**ОГРАБЛЯ'ТЬСЯ** *несов. страд. просторечс.* — талану.

**ОГРА'ДА** *ж. книж.* — 1. киртә, койма; 2. *перен. устар.* (*защита, охрана*) яклаучы, саклаучы, сакчы.

**ОГРАДИ'ТЬ** *сов. книж.* — 1. *устар.* (*обнести оградой* или *отгородить*) киртәләү, коймалау, киртә тотып чыгу; 2. *перен.* чик кую, ... -дан саклау; *оградить себя от лишних волнений* — үзеңне артык борчулардан саклау.

**ОГРАДИ'ТЬСЯ** *сов. книж.* — чикләнү, саклану, аерылу.

**ОГРАЖДА'ТЬ** *несов. книж.* — к. оградить.

**ОГРАЖДА'ТЬСЯ** *несов. книж.* — 1. к. оградиться; 2. *страд.* киртәләнү, коймалану (киртә, койма белән әйләндереп алыну).

**ОГРАЖДЕ'НИЕ** *ср. книж.* — 1. *только ед.* (*действие*) к. оградить; 2. *устар.* (*ограда, заграждение*) киртә, койма.

**ОГРА'НИВАТЬ** *несов.* — кырлау, кырлап шомарту (пыяланы, каты ташны).

**ОГРА'НИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — кырлану, кырып шомартылу.

**ОГРАНИ'ТЬ** *сов.* — к. огранивать.

**ОГРАНИЧЕ'НИЕ** *ср. книж.* — чикләү, чик кую; *без всяких ограничений* — һичбер чик куймыйча.

**ОГРАНИ'ЧЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — 1. чикләнгәнлек, чиклелек; аз булу; *ограниченность средств* — акчаның аз булуы; 2. тарлык, сайлык; *ограниченность ума* — акыл тарлыгы; *умственная ограниченность* — акыл сайлыгы.

**ОГРАНИ'ЧЕННЫЙ** — 1. чик куелган, чикләнгән; 2. *книж.* урап алынган, чор-

нап алынган, чикләнгән; *местность, ограниченная горами* — таулар белән чикләнгән урын; 3. *перен.* чикләнгән, чикле күләмдәге, аз; *ограниченные средства* — чикле күләмдәге акча; 4. *перен.* тар фикерле, тар карашлы; *он был чрезвычайно неразвит, ограничен и большая тупица* — ул бик артка калган, тар карашлы һәм бик аңгыра кеше иде.

**ОГРАНИ'ЧИВАТЬ** *несов.*— к. ограничить.

**ОГРАНИ'ЧИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. ограничиться; 2. *страд.* чикләнү, чик куелу.

**ОГРАНИЧИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.* — чикли торган, чик куя торган, чикле; *ограничительное распоряжение* — чик куя торган боерык.

**ОГРАНИ'ЧИТЬ** *сов.* — чикләү, чик кую, кыса төшү; *ограничить в правах* — хокукларын чикләү; *ограничить себя в расходах* — үзеннең расходларыны кыса төшү.

**ОГРАНИ'ЧИТЬСЯ** *сов.* — чикләнү; *ограничиться краткой речью* — кыска гына речь белән чикләнү.

**ОГРАНЯ'ТЬ** *несов.* — к. огранивать.

**ОГРАНЯ'ТЬСЯ** *несов.* — к. ограниваться.

**ОГРЕБА'ТЬ** *несов.* — көрәү. ◇ **Огребать деньги** *простореч.* — акчаны көрәк белән көрәп алу (күп акча эшләү мәгънәсендә). **Хоть лопатой огребай** — бик күп, көрәк белән көрәрлек.

**ОГРЕБА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. огрестись; 2. *страд.* көрәлү, көрәп алыну.

**ОГРЁБКИ** *ед.* нет, *обл.* — печән калдыклары (кибән салганнан соң).

**ОГРЕ'БЬЕ** *ср. мн.* нет, *собир. обл.* — к. огребки.

**ОГРЕВА'ТЬ** *несов. простореч. обл.* — к. огреть.

**ОГРЕСТИ'** *сов.* — 1. көрәү, көрәп кую; *огрести снег вокруг дома* — өй тирәсендәге карны көрәп кую; 2. *обл.* тарап чыгу; *огрести стог* — кибәнне тарап чыгу.

**ОГРЕСТИ'СЬ** *сов. простореч.* — кагып төшерү; *огрестись от снегу* — карны өстән кагып төшерү. ◇ **Хлопот не огребёшься** — мәшәкатеннән йөдәрсең.

**ОГРЕ'ТЬ** *сов.* — 1. *обл.* к. обогреть; 2. *простореч.* тондыру, кундыру; *так бы вот тебя по лысине и огрела* (А. Островский) — менә синең пеләш башыңа берне кундырыр идем.

**ОГРЕ'Х** *м.* — 1. *с.-х.* чи калган җир (сөргәндә); 2. *простореч.* (*ошибка, промашка*) хата; хата җибәрү, ялгышу.

**ОГРО'МНЫЙ** — бик зур, бик дәү, чиксез зур; *огромный дом* — бик зур өй; *огромные задачи* — бик зур бурычлар.

**ОГРУБЕВА'ТЬ** *несов. устар.*— к. огрубеть.

**ОГРУБЕ'ЛОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — тупаслык, дорфалык; *огрубелость нравов*— гадәтләрнең тупаслыгы.

**ОГРУБЕ'ТЬ** *сов.* — 1. тупаслану, дорфалану; 2. кытыршылану; *кожа огрубела* — тире кытыршыланды. ◇ **Голос огрубел** — тавыш калынайды, тавыш тупасланды.

**ОГРУЖА'ТЬ** *несов. устар.*— к. огрузить.

**ОГРУЗА'ТЬ** *несов.* — к. огрузнуть.

**ОГРУЗИ'ТЬ** *сов. устар.* — кирәгеннән артык йөк төяү; *огрузить корабль* — корабльгә кирәгеннән артык йөк төяү.

**ОГРУ'ЗЛЫЙ** *спец.* — суга тирән утырган; *огрузлая барка* — суга тирән утырган барка (күп йөк төяүдән).

**ОГРУ'ЗНУТЬ** *сов.* — 1. (*спуститься на дно*) төпкә утыру, тирән утыру (кирәгеннән артык бату); *барка огрузла* — барка тирән утырган; 2. *разг.* акрын кыймылдый башлау, сүлпәнләнү, авыраю; *огрузнуть от обжорства* — чиктән тыш күп ашап авыраю.

**ОГРЫЗА'ТЬ** *несов. простореч.* — к. огрызть.

**ОГРЫЗА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. (*о собаке*) ырылдау; 2. *разг. перен.* (*грубо ответить*) тупас, кискен җавап бирү.

**ОГРЫЗНУ'ТЬСЯ** *сов.* — к. огрызаться.

**ОГРЫ'ЗОК** *м. разг.* — 1. кимерек (кимергәннән калган кисәк); 2. *перен. пренебр.* кисәк; *огрызок карандаша* — карандаш кисәге.

**ОГРЫ'ЗТЬ** *сов. простореч.* — к. обгрызть.

**ОГУ'ЗОК** *м. спец.* — 1. (*мясо из средней части бедра*) сум ите; 2. (*шкурка, мех с задней части животного*) арт сан тиресе.

**ОГУ'ЛОМ** *нареч. разг.* — 1. (*валом, гуртом*) күпләп, күмәртәләп, ишле итеп; 2. (*без разбора*) тикшермичитмичә; тикшереп тормастан; 3. *устар. обл.* (*целиком, оптом*) тулаем.

**ОГУ'ЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *разг.* — дәлилсез булу, дәлилсезлек.

**ОГУ'ЛЬНЫЙ** *разг.* — 1. һичбер нигезсез, дәлилсез; *огульные обвинения* — дәлилсез гаепләүләр; 2. *устар.* күмәртәле; *огульная торговля*— күмәртәле сәүдә.

**ОГУРЕ'Ц** *м.* — кыяр.

**ОГУРЕ'ЧНЫЙ** — кыяр...-ы; *огуречные семена* — кыяр орлыклары.

**ОГУ'РЧИК** *м. разг.* — 1. кечкенә кыяр; 2. *перен. шутл. простореч.* (*о человеке крепкого, свежего вида*) таза, сәламәт кыяфәтле кеше; алма кебек йөзле кеше.

**О'ДА** *ж.* — ода, мактау шигыре, мәдхия.

**ОДАЛИ'СКА** *ж.*—кәнизәк.

**О'ДАЛЬ** *нареч. устар. обл.* — ары, арырак, читтә, читтәрәк; *одаль молодцы стоят* — арырак егетләр басып торалар.

**ОДАРЁННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — талантлылык, сәләтлелек; *изучение одарённости детей* — балаларның сәләтлелеген тикшерү.

**ОДАРЁННЫЙ** *книж.* — 1. бүләкләнгән; 2. (*талантливый, даровитый*) талантлы, сәләтле.

**ОДА'РИВАТЬ** *несов. разг.*— к. одарить 1.

**ОДА'РИВАТЬСЯ** *несов. страд. разг.* — бүләкләнү, бүләкләр бирелү.

**ОДАРИ'ТЬ** *сов.* — 1. (*наделить подарками*) бүләкләү, бүләк бирү, бүләк бирен чыгу, бүләкләр өләшеп чыгу; 2. *перен.* бирү, бүләкләү; *природа одарила его редкими способностями* — табигать аңа сирәк очрый торган сәләтләр биргән.

**ОДАРЯ'ТЬ** *несов. устар.* — к. одарить.

**ОДАРЯ'ТЬСЯ** *несов. книж. устар.* — к. одариваться.

**ОДЕВА'ТЬ** *несов.* — к. одеть.

**ОДЕВА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. киенү, киенеп йөрү; *я сейчас буду одеваться* — мин хәзер киенә башлыйм; *он одевался хорошо* — ул яхшы киенеп йөри иде; 2. *устар.* кием тектерү; *одеваться у хорошего портного* — яхшы тегүчедән кием тектерү; 3. *страд.* киендерелү, кием белән тәэмин ителү.

**ОДЁЖА** *ж. простореч.* — кием, кием-салым.

**ОДЕ'ЖДА** *ж.* — кием, кием-салым, өс-баш; *верхняя одежда* — өске кием. ◇ **Асфальтовая одежда** *тех.* — асфальт җәелгән юл.

**ОДЁЖИНА** *ж. простореч. обл.* — кием-салымнан бер әйбер.

**ОДЁЖКА** *ж. простореч.* — кием, кием-салым. ◇ **По одёжке протягивай ножки** — юрганыңа карап аягыңны суз.

**ОДЕЖО'НКА** *ж. мн.* нет, *разг.* — начар кием, иске кием.

**ОДЕКОЛО'Н** *м.* — одеколон, ислемай.

**ОДЕКОЛО'НИТЬСЯ** *несов. простореч.* — одеколон сөртенү, ислемай сөртенү.

**ОДЕКОЛО'ННЫЙ** — одеколон...-ы; ислемай...-ы; *одеколонный запах* — одеколон исе, ислемай исе.

**ОДЕЛИ'ТЬ** *сов. книж.* — 1. бүләк итеп бирү, бүләк өләшү; *он оделил игрушками всех детей* — ул балаларның барысына да бүләк итеп уенчыклар бирде; 2. *перен. устар.* бирү, мул итеп бирү; *природа щедро оделила его способностями* — табигать аңа мул итеп төрле сәләтләр биргән.

**ОДЕЛЯ'ТЬ** *несов. книж.* — к. оделить.

**ОДЕЛЯ'ТЬСЯ** *несов. книж. страд.* — өлеш чыгарылу, бүләк итеп бирелү.

**ОДЁР** *м. простореч. презрит.* — 1. (*старая изнурённая лошадь*) арык эш аты; арык ат; 2. *перен. бран.* (*о человеке, крайне исхудалом, нескладном*) ябык һәм килбәтсез кеше, чандыр кеше.

**ОДЁРГАТЬ** *сов. простореч.* — к. обдёргать.

**ОДЁРГИВАТЬ** I *несов. простореч.* — к. одёргать.

**ОДЁРГИВАТЬ** II *несов.* — к. одёрнуть.

**ОДЁРГИВАТЬСЯ** I *несов. страд. простореч.* — тирәли йолкып чыгылу, йолкып тигезләнү (мәсәлән, печән йөге турында).

**ОДЁРГИВАТЬСЯ** II *несов. разг.* — к. одёрнуться.

**ОДЕРЕВЕНЕ'ЛОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. агачка әверелү; 2. катып калу; 3. өю (аяк, кул турында).

**ОДЕРЕВЕНЕ'ЛЫЙ** — каткан, катып калган, агач кебек булган; *одеревенелые пальцы* — каткан бармаклар. ◇ **Впасть в одеревенелое состояние** — бернәрсә дә сизми башлау.

**ОДЕРЕВЕНЕ'ТЬ** *сов.* — к. деревенеть.

**ОДЕРЖА'ТЬ** *сов. книж.*: **одержать победу** — җиңеп чыгу; **одержать верх** — өстен чыгу.

**ОДЕ'РЖИВАТЬ** *несов.* — к. одержать.

**ОДЕРЖИ'МОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — нык бирелгәнлек.

**ОДЕРЖИ'МЫЙ** *книж.* — 1. нык бирелгән, бирелгән; *одержимый страхом* — куркуга бирелгән; 2. *в знач. сущ.* (*безумный человек*) шашкан кеше, тиле.

**ОДЁРНУТЬ** *сов.* — 1. (*потянув, оправить*) тартып рәтләп кую, тартып рәтләү, тартып җайлау; *одёрнуть платье* — күлмәкне тартып рәтләп кую; 2. *перен. разг.* (*оборвать, заставить замолчать*) кискен рәвештә сүзен өзү, телен тыю, авызын томалау.

**ОДЁРНУТЬСЯ** *сов. разг.* — тартып рәтләп кую, тартып җайлап кую, тартып иплэп кую (өскә кигән әйберне).

**ОДЕСНУ'Ю** *нареч. книж. старин.* — уң якта.

**ОДЕ'ТЫЙ** — 1. киенгән, киенгән килеш; *хорошо одетый* — яхшы киенгән; *он лежал одетый* — ул киенгән килеш ята иде; 2. *перен.* капланган; *поля одеты снегом* — кырлар кар белән капланган.

**ОДЕ'ТЬ** *сов.* — 1. киендерү; *одеть ребёнка* — баланы киендерү; 2. ябу; *одеть больного одеялом* — авыруның өстенә юрган ябу; 3. *поэт.* каплау, каплап алу; *зима одела поля снегом* — кыш басуларны кар белән каплаган; 4. өстен бөтәйтү; *все мы одеты* — барыбызның да өс-баш бөтен.

**ОДЕ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. киенү; *он молча оделся* — ул дәшми-тынмый гына киенде; 2. *разг.* (*приобрести одежду*) кием-салым алу, өс-башны бөтәйтү, киенү; 3. *разг.* төренү, ябыну; *одеться одеялом* — юрганга төренү, юрган ябыну; 4. *перен. поэт.* төренү, каплану; *деревья оделись листвой* — агачлар яфраклар белән капланган.

**ОДЕЯ'ЛИШКО** *ср. простореч. уничиж.* — юрган кисәге, начар юрган.

**ОДЕЯ'ЛО** *ср.* — юрган, одеял.

**ОДЕЯ'ЛЬЦЕ** *ср. разг.* — балалар юрганы, кечкенә юрган.

**ОДЕЯ'ЛЬЩИК** *м. спец.* — юрган сыручы.

**ОДЕЯ'НИЕ** *ср. книж. устар.* — кием-салым, бәйрәм киеме.

**ОДИ'Н** *числит.* — 1. *только ед.* бер; 2. ялгыз, бер үзе; *я остался дома один* — мин өйдә ялгыз калдым; *я живу один* — мин бер үзем торам; 3. ...гына; *одна канитель мне с тобой* — бәла генә булдың син миңа; 4. бер нәрсә; *одно только меня беспокоит* — мине бер генә нәрсә борчый. ◇ **Один-одинёшенек, один одинёхонек** *разг.* — япа-ялгыз. **Одно и тоже** — бер үк нәрсә, шул ук нәрсә. **Он говорил со мной один на один** — ул минем белән күзгә-күз сөйләште. **Один в поле не воин** — бер тиредән тун булмас, бер тарыдан ботка булмас. **Все до одного** — барысы да. **Все как один** — барысы да бер кеше кебек, бердәм булып. **Один за другим** — берәм-берәм, бер-бер артлы. **Одно к одному** — берсе өстенә берсе. **В одних руках** — бер кеше кулында, бер кулда. **Всё одно** — барыбер. **Одним духом** — берьюлы, тоташтан, тын алмыйча. **Одним**

словом — кыскасы, кыскача әйткәндә, бер сүз белән әйткәндә.

**ОДИНА'КИЙ** *простореч.* — к. одинаковый.

**ОДИНА'КОВОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — бертөрлелек, бертөслелек, бертигезлек, бердәйлек; *одинаковость образа мыслей* — фикер йөртүнең бертөрлелеге.

**ОДИНА'КОВЫЙ** — бертөрле, бертөсле, бертигез, бердәй; *одинаковые взгляды на вещи* — әйберләргә бертөсле караш.

**ОДИНА'РНЫЙ** — бер инле; *одинарная материя* — бер инле материя.

**ОДИНЁХОНЕК, ОДИНЁШЕНЕК** *ласкат.* — япа-ялгыз.

**ОДИ'ННАДЦАТЫЙ** — унберенче.

**ОДИ'ННАДЦАТЬ** *числит. колич.* — унбер.

**ОДИ'НОЖДЫ** *нареч.* — бер тапкыр; *одиножды пять — пять* — бер тапкыр биш — биш була.

**ОДИНО'КИЙ** — 1. ялгыз; *одинокий хутор* — ялгыз хутор; 2. ялгыз, буш-буйдак, кардәш-ырусыз; *я человек одинокий* — мин ялгыз кеше.

**ОДИНО'КОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — ялгызлык.

**ОДИНО'ЧЕСТВО** *ср. мн.* нет, *книж.* — ялгызлык; *в одиночестве способен жить не всякий* — ялгызлыкта һәркем дә яши алмый.

**ОДИНО'ЧКА** *м.* и *ж.* — 1. *разг.* ялгыз; *живет одиночкой* — ялгыз яши; 2. *неодобр.* (*о человеке, отчуждённом от общественных интересов*) читтә торучы кеше, аралашмаучан кеше; 3. *разг.* (*камера для одиночного заключения*) одиночка (төрмәдә бер кешелек бүлмә); 4. *спорт.* (*лодка, в которой помещается только один гребец*) бер кешелек көймә. ◇ **В одиночку** *разг.* — бер үзе, япа-ялгыз, ялгыз. **По одиночке** *разг.* — берәм-берәм, берәмләп.

**ОДИНО'ЧНИК** *м.*, **ОДИНО'ЧНИЦА** *ж.* *разг.* — одиночник (төрмәдә үзе генә бер камерада утыручы кеше).

**ОДИНО'ЧНЫЙ** — 1. ялгыз; *одиночный лётчик* — ялгыз лётчик; 2. бер кешелек; *одиночная камера* — бер кешелек камера; 3. ялгыз, аерым; *переход от одиночного хозяйства к крупному общественному* — ялгыз хуҗалыктан күмәкләштерелгән эре хуҗалыкка күчү. ◇ **Одиночные выстрелы** — берәм-сәрәм атулар.

**ОДИО'ЗНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — куркынычлылык, күңелсезлек.

**ОДИО'ЗНЫЙ** *книж.* — куркынычлы, күңелгә ошамый торган, сөйкемсез; *одиозная личность* — сөйкемсез кеше.

**ОДИССЕ'Я** *ж. книж.* — одиссея (күп сәяхәтләрдә мажаралар белән үткән тормыш, шуның турында хикәя; борынгы грек язучысы Гомер әсәренең Троян сугышы герое Одиссей исеменнән алынган.)

**ОДИЧА'ЛОСТЬ** *ж. мн.* нет — кыргыйланганлык, кыргыйлашканлык.

**ОДИЧА'ЛЫЙ** — кыргыйланган, кыргыйлашкан; *одичалый конь* — кыргыйлашкан ат.

**ОДИЧА'ТЬ** *сов.* — к. дичать.

**ОДИ'ЧЕСКИЙ** *лит.* — ода...-ы, одага хас; *одический стиль* — ода стиле.

**ОДНА'ЖДЫ** *нареч.* — 1. (*один раз*) бер кат, бер тапкыр, бер кабат; 2. (*когда-то*) бер заман, бер көн, көннәрдән бер көн; 3. *простореч.* (*когда-н.*) кайчан да бер.

**ОДНА'КО** — 1. *союз противительный* ләкин, әмма, мәгәр, шулай да; *обещал, однако не исполнил* — вәгъдә бирде, ләкин сүзендә тормады; 2. *в знач. ввод. сл.* шулай да, шулай булса да; *чего же, однако, ты испугался?* — шулай да, син нәрсәдән курыктың соң? 3. *разг. в знач. междом.* ай-һай; *однако, накурено у вас здесь* — ай-һай, сез монда күп тәмәке тарткансыз.

**ОДНА'КОЖ, ОДНА'КОЖЕ** — к. однако.

**ОДНОА'КТНЫЙ** *театр.* — бер актлы, бер пәрдәле; *одноактная пьеса* — бер пәрдәле пьеса.

**ОДНОБО'КИЙ** — 1. *разг. фам.* (*с одним боком*) бер яклы, бер янлы; 2. *перен.* берьяклы, бер яктан гына чыгып; *однобокое суждение* — берьяклы фикер йөртү.

**ОДНОБО'КОСТЬ** *ж. мн.* нет — берьяклылык, берьяклы булу, берьякны гына иска алу.

**ОДНОБО'РТНЫЙ** — бер капламалы, бер генә якка каплана торган (өс киеме).

**ОДНОБРА'ЧНЫЙ** *бот.* — ике өйле (үсемлекләр).

**ОДНОВЕСЕ'ЛЬНЫЙ** *мор.* — бер ишкәкле.

**ОДНОВРЕ'МЕ'ННО** *нареч.* — бер үк вакытта.

**ОДНОВРЕ'МЕ'ННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — бер үк вакытта булу.

**ОДНОВРЕ'МЕ'ННЫЙ** *книж.* — бер үк вакытта була торган, бер үк вакыттагы; *одновременные события* — бер үк вакыттагы вакыйгалар.

**ОДНОГЛА'ЗКА** *ж. зоол.* — циклоп, сынар күз (кыслачык).

**ОДНОГЛА'ЗЫЙ** — бер күзле, сынар күзле.

**ОДНОГОДИ'ЧНЫЙ** *книж.* — берьеллык...; бер елга сузыла торган; *одногодичная командировка* — берьеллык командировка.

**ОДНОГО'ДОК** *м.* — 1. *разг.* яшьтәш; 2. *обл.* бер яшьлек (терлек турында).

**ОДНОГО'РБЫЙ** — бер өркәчле; *одногорбый верблюд* — бер өркәчле дөя.

**ОДНОДВО'РЕЦ** *м.*, **ОДНОДВО'РКА** *ж.* — 1. *истор.* однодворец (Москва Русендә түбән дәрәҗәле дәүләт хезмәтендә булган кешеләрдән чыккан крестьян); 2. йортташ, ихатадаш, бер үк йортта торучы.

**ОДНОДЕРЁВКА** *ж. спец. обл.* — чокып ясалган көймә.

**ОДНОДНЕ'ВКА** *ж. зоол.* — бер көн генә яши торган бөҗәк, бер көнлек күбәләк.

**ОДНОДНЕ'ВНЫЙ** — бер көнлек; *однодневный дом отдыха* — бер көнлек ял йорты.

**ОДНОДО'ЛЬНЫЙ** *бот.* — сынар орлыклы (үсемлекләр).

**ОДНОДО'МНЫЙ** *бот.*— бер өйле (аерым җенесле чәчәкләре бер үк төптә була торган үсемлек).

**ОДНОДУ'М** *м.*— бер нәрсә турында гына уйлый торган кеше.

**ОДНОЗАРЯ'ДНЫЙ** *воен.*— бер зарядлы; *однозарядное ружьё* — бер зарядлы мылтык.

**ОДНОЗВУ'ЧНЫЙ** *книж. поэт.*— күңелсез, бер төрле, ялыктыргыч тавышлы (кыңгырау һ. б.).

**ОДНОЗЕРНЯ'НКА** *ж. бот.*— бер башакчыклы борай (борайның борынгы бер төре, һәрбер башакчыгында бер генә бөртек булган борай).

**ОДНОЗНА'ЧАЩИЙ** *книж.*— к. однозначный.

**ОДНОЗНА'ЧНЫЙ** — 1. *книж.* бер мәгънәле, мәгънәдәш, мәгънәсе бер (сүз); 2. *мат.* бер урынлы (сан).

**ОДНОИМЁННЫЙ** — бер исемдәге, исемдәш; *одноимённые города* — исемдәш шәһәрләр, бер исемдәге шәһәрләр.

**ОДНОКАЛИ'БЕРНЫЙ** *спец.*— бер үк калиберлы, калиберлары бертөрле булган; *однокалиберные винтовки* — бер үк калибрдагы винтовкалар.

**ОДНОКА'ШНИК** *м. разг. устар.*— бергә укыган кеше, сабакташ, шәрик.

**ОДНОКВАРТИ'РНЫЙ** — бер квартиралы; *одноквартирный дом* — бер квартиралы өй.

**ОДНОКЛА'ССНИК** *м.*, **ОДНОКЛА'ССНИЦА** *ж.*— классташ (мәктәптә).

**ОДНОКЛЕ'ТОЧНЫЙ** *биол.*— бер күзәнәкле; *одноклеточные организмы* — бер күзәнәкле организмнар.

**ОДНОКЛУ'БНИК** *м.* — клубташ (бер спорт оешмасының членнары).

**ОДНОКОЛЕ'ЙКА** *ж. разг.*— бер колеялы (тимер юл).

**ОДНОКОЛЕ'ЙНЫЙ** *спец.*— бер колеялы; *одноколейный путь* — бер колеялы юл.

**ОДНОКО'ЛКА** *ж. разг.* — бер күчәрле арба.

**ОДНОКО'ННЫЙ** — бер атлы, бер ат җигә торган; *одноконный плуг* — бер атлы сабан.

**ОДНОКОПЫ'ТНЫЙ** *зоол.*— 1. сыңар тояклы (ат, качыр һ. б.); 2. *в знач. сущ.* сыңар тояклылар.

**ОДНОКОРЫ'ТНИК** *м.*— 1. табакташ, бер табактан ашап үскән (гадәттә этләр); 2. *перен. простореч. шутл.* сабакташ, дус, иптәш.

**ОДНОКРА'ТНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— бер генә тапкыр булу, бер кабат кына булу.

**ОДНОКРА'ТНЫЙ** *книж.* — бер тапкыр, бер кабат (булган, эшләнгән). ◇ Однократный вид глагола *грам.*— кабатлаусыз фигыль.

**ОДНОЛА'МПОВЫЙ** *радио* — бер лампалы; *одноламповый радиоприёмник* — бер лампалы радиоалгыч.

**ОДНОЛЕ'ТНИЙ** *книж.*—1. (*продолжающийся один год*) берьеллык; 2. *бот.* бер җәйлек; *однолетние травы* — бер җәйлек үләннәр; 3. *редко* бер яшьлек; *однолетний мальчуган* — бер яшьлек малай.

**ОДНОЛЕ'ТНИК** *м. бот.* — берьеллык үсемлек (мәсәлән, житен, көнбагыш).

**ОДНОЛЕ'ТОК** *м. разг.*— яшьтәш; *мы с ним однолетки* — без аның белән яшьтәшләр.

**ОДНОЛОША'ДНЫЙ** — бер атлы; *однолошадное хозяйство* — бер атлы хуҗалык.

**ОДНОМА'ЧТОВЫЙ** — бер мачталы; *одномачтовое судно* — бер мачталы судно.

**ОДНОМЕ'СТНЫЙ** *спец.* — бер урынлы, бер кешелек; *одноместная каюта* — бер кешелек каюта.

**ОДНОМОТО'РНЫЙ** *тех.*— бер моторлы.

**ОДНОНО'ГИЙ** — бер аяклы, сыңар аяклы.

**ОДНООБРА'ЗИЕ** *ср. мн.* нет — бертөрлелек, үзгәрешсезлек, бертөслелек; *томительное однообразие* — эч пошыргыч бертөрлелек.

**ОДНООБРА'ЗНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— к. однообразие.

**ОДНООБРА'ЗНЫЙ** — бертөрле, үзгәрешсез, күңелсез, эч пошыргыч; *однообразная жизнь* — үзгәрешсез тормыш.

**ОДНОПАЛА'ТНЫЙ** *полит.*— бер палаталы; *однопалатная парламентская система* — бер палаталы парламент системасы.

**ОДНОПА'ЛУБНЫЙ** *мор.*— бер палубалы, бер катлы; *однопалубное судно* — бер палубалы судно.

**ОДНОПА'ЛЫЙ** *спец. простореч.*— 1. бер бармаклы; 2. сыңар тояклы (мал).

**ОДНОПЛЕМЕ'ННЫЙ** — ырудаш, кабиләдәш, бер кабиләдән, бер ырудан.

**ОДНОПЛЕ'ЧИЙ** *тех.*— бер терсәкле; *одноплечий рычаг* — бер терсәкле рычаг.

**ОДНОПО'ЛОСТЬ** *ж. мн.* нет, *бот.*—бер женеслелек.

**ОДНОПОЛЧА'НИН** *м. разг.*— полкташ, бер үк полк кешесе (армиядә).

**ОДНОПО'ЛЫЙ** *бот.*—бер женесле (үсемлек).

**ОДНОПУ'ТКА** *ж. разг.*—бер колеялы тимер юл.

**ОДНОПОМЁТНИК** *м. спец.*— игезәк (эт балалары).

**ОДНОРО'ГИЙ** — бер мөгезле.

**ОДНОРО'ДНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— бертөслелек, охшашлык, бертөрлелек.

**ОДНОРО'ДНЫЙ** *книж.* — 1. бертөрле; 2. *грам.* тиңдәш; *однородные члены предложения* — җөмләнең тиңдәш кисәкләре.

**ОДНОРУ'КИЙ** — бер куллы, сыңар куллы, чулак.

**ОДНОРУ'ЧНЫЙ** *спец.* — бер тоткалы, бер саплы; *одноручная пила* — бер тоткалы пычкы.

**ОДНОРЯ'ДКА** *ж. истор.*— озын җилән (борынгы Русьта бер рәт төймә тезелгән кием).

**ОДНОСЕЛЬЧА'НИН** *м.*, **ОДНОСЕЛЬЧА'НКА** *ж.*— авылдаш.

**ОДНОСЕ'ТЧАТЫЙ** *радио* — бер челтәрле;

*односетчатая лампа радиоприёмника* — радиоприёмникның бер челтәрле лампасы.

**ОДНОСИ'ЛЬНЫЙ** *тех.* — бер егәрле, бер ат көче булган; *односильный мотор* — бер ат көче булган мотор.

**ОДНОСКА'ТНЫЙ** — бер кыеклы; *односкатная крыша* — бер кыеклы түбә.

**ОДНОСЛО'ЖНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — 1. *грам.* бер иҗеклелек, бер иҗекле булу; 2. өзек-өзек булу, кыска булу; *односложность ответов* — җавапларның кыска булуы.

**ОДНОСЛО'ЖНЫЙ** *книж.* — 1. бер иҗекле; *односложные слова* — бер иҗекле сүзләр; 2. өзек-өзек, кыска; *односложный ответ* — кыска җавап.

**ОДНОСПА'ЛЬНЫЙ** — бер кешелек (бер генә кеше йокларлык, ябынырлык итеп эшләнгән); *односпальная кровать* — бер кешелек кровать; *односпальное одеяло* — бер кешелек юрган.

**ОДНОСТВО'ЛЬНЫЙ** *воен.* — бер көпшәле; *одноствольное ружьё* — бер көпшәле мылтык.

**ОДНОСТВО'РЧАТЫЙ** — бер генә якка ачыла торган; *одностворчатый шкаф* — бер генә якка ачыла торган шкаф.

**ОДНОСТО'ПНЫЙ** *лит.* — бер стопалы; *одностопный стих* — бер стопалы шигырь.

**ОДНОСТОРО'ННИЙ** — 1. *только полн. формы* берьяклы; *односторонний плеврит* — берьяклы плеврит; 2. ике ягы ике төрле; *односторонняя ткань* — бер яклы (ике ягы ике төрле) тукыма; 3. *перен. книж.* берьяклы, тар, тар карашлы; *одностороннее воспитание* — берьяклы тәрбия; *односторонний человек* — тар карашлы кеше.

**ОДНОСТОРО'ННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — тар карашлылык, чикләнгәнлек, берьяклылык.

**ОДНОСТРУ'ННЫЙ** *спец.* — бер кыллы (музыка коралы).

**ОДНОТИ'ПНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — бер үк типта булу.

**ОДНОТИ'ПНЫЙ** *книж.* — бер типтагы, бер үк типтагы, бер формадагы, охшаш.

**ОДНОТО'МНИК** *м.* — бер томлык (басма).

**ОДНОТО'МНЫЙ** — бер томлы; *однотомное издание сочинений классиков* — классик язучылар әсәрләренең бер томлы басмасы.

**ОДНОУТРО'БНЫЙ** *разг.* — к. единоутробный.

**ОДНОУ'ХИЙ** — бер колаклы; *одноухий щенок* — бер колаклы көчек.

**ОДНОФАМИ'ЛЕЦ** *м.*, **ОДНОФАМИ'ЛИЦА** *ж.* — фамилиядәш.

**ОДНОЦВЕ'ТНЫЙ** — 1. бер генә төстәге, бер генә буяулы; бер үк төстәге; *одноцветные обои* — бер генә төстәге обойлар; 2. *перен. книж.* (*однообразный, монотонный*) күңелсез, эч пошыргыч, бертөрле.

**ОДНОЧА'СЬЕ** *ср. мн.* нет, *обл.* — бер сәгать вакыт, бер сәгать эчендә; *в одночасье умер, никто и не ждал* — һичкем көтмәгәндә, бер сәгать эчендә үлде дә китте.

**ОДНОЧЛЕ'Н** *м. мат.* — бербуын.

**ОДНОЧЛЕ'ННЫЙ** — 1. бер әгъзалы; 2. *мат.* бербуынлы; *одночленная формула* — бербуынлы формула.

**ОДНОШЕ'РСТНЫЙ**, **ОДНОШЁРСТНЫЙ** — йоннары бертөсле булган; бертөсле; *одношерстные кони* — бертөсле атлар.

**ОДНОЭТА'ЖНЫЙ** — бер катлы; *одноэтажный дом* — бер катлы йорт.

**ОДОБРЕ'НИЕ** *ср. книж.* — 1. (*действие*) к. одобрить; 2. (*похвала*) мактау, яхшы дип табу, хуплау, хуп күрү.

**ОДОБРИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.* — яхшы, яраклы, мактаулы; *одобрительный отзыв* — яхшы отзыв.

**ОДО'БРИТЬ** *сов.* — 1. яраклы дип тану; яхшы дип тану; мактау, хуплау; 2. *офиц.* рөхсәт итү, тәкъдим итү; *одобрить книгу к печатанию* — китапны басарга тәкъдим итү.

**ОДОБРЯ'ТЬ** *несов.* — к. одобрить.

**ОДОБРЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. яраклы дип танылу, яхшы дип танылу, макталу; 2. рөхсәт ителү.

**ОДОЛЕВА'ТЬ** *несов.* — к. одолеть.

**ОДОЛЕВА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. җиңелү; 2. комачаулану, йөдәтелү, борчылу; 3. буйсындырылу, үзләштерелү.

**ОДОЛЕ'ТЬ** *сов.* — 1. җиңү, өстен чыгу, җиңеп чыгу; *одолеть противника* — дошманны җиңеп чыгу; 2. *разг.* йөдәтеп бетерү, комачаулау, аптырату, борчу; *кашель одолел* — ютәл йөдәтеп бетерде; 3. *перен.* (*завладеть, подчинить*) тулысынча буйсындыру; 4. *разг.* ия булу, үзләштерү; *одолеть математику* — математиканы үзләштерү; 5. *редко* үзен-үзе кулга алу; *она собиралась заплакать, но одолела себя* — ул елар хәлгә җиткән иде, ләкин үзен-үзе кулга алды.

**ОДОЛЖА'ТЬ** *несов.* — к. одолжить.

**ОДОЛЖА'ТЬСЯ** *несов.* — бурычлы булу, ярдәм күрү. ◇ **Одолжайтесь** *пов. накл. фам. устар.* — рәхим итегез.

**ОДОЛЖЕ'НИЕ** *ср. книж.* — яхшылык күрсәтү, яхшылык эшләү; *поблагодарить за одолжение* — яхшылык эшләгән өчен рәхмәт белдерү. ◇ **Сделайте одолжение** *разг.* — зинһар, зинһар өчен дип әйтәм; *поедем, сделай одолжение* — зинһар өчен дип әйтәм, әйдә китик.

**ОДОЛЖИ'ТЬ** *сов.* — 1. бурычка бирү, әҗәткә бирү, үтечкә бирү; *одолжите сто рублей* — бурычка йөз сум акча биреп торыгыз әле; 2. (*взять в долг*) бурычка алу; 3. *устар. теперь шутл. ирон.* (*оказав услугу, обязать благодарностью*) үзенә бурычлы дип санау (яхшылык күрсәткән өчен).

**ОДОМА'ШНИВАТЬ** *несов. спец.* — к. одомашнить.

**ОДОМА'ШНИВАТЬСЯ** *несов. спец.* — 1. к. одомашниться; 2. *страд.* кулга ияләштерелү.

**ОДОМА'ШНИТЬ** *сов. спец.* — ияләштерү, кулга ияләштерү.

**ОДОМА'ШНИТЬСЯ** *сов. спец.*— нялэшү, кулга нялэшү.
**ОДОНТО'ЛОГ** *м. мед.*— одонтолог (одонтология белгече).
**ОДОНТОЛОГИ'ЧЕСКИЙ** *мед.* — одонтология...-ы; *одонтологический кабинет* — одонтология кабинеты.
**ОДОНТОЛО'ГИЯ** *ж. мн.* нет, *мед.* — одонтология (тешләр һәм аларны дәвалау турындагы фән).
**ОДР** *м. устар. книж.*— түшәк, ятак; *смертный одр* — үлем түшәге.
**ОДРЕВЕСНЕ'ТЬ** *сов. спец.*— кату, агачлану (үсемлекләрнең күзәнәкләре, яшь ботаклары турында).
**ОДРЯБЛЕ'ТЬ** *сов. просторечь.* — сәлперәю, көпшәкләнү, муртаю; *бревно одряблело* — бүрәнә муртайган.
**ОДРЯ'БНУТЬ** *сов. просторечь.*— к. одряблеть.
**ОДРЯХЛЕ'ЛЫЙ** *просторечь.*— какшаган, картайган, йончыган, бетерешкән; *одряхлелый старик* — бетерешкән карт.
**ОДРЯХЛЕ'ТЬ** *сов.*— какшау, картаю, бетерешү.
**ОДРЯ'ХНУТЬ** *сов. разг.*— к. одряхлеть.
**ОДУВА'НЧИК** *м.*— тузганак, йонлы баш, сыргa үләне.
**ОДУ'ЛЫ** *м.*— юкагир халкы, одул халкы (Якутия АССРның төньяк-көнчыгыш районнарында һәм Хабаровск краенда яшәүче халык).
**ОДУ'ЛЬСКИЙ** — одуллар...-ы; *одульский обычай* — одуллар гадәте.
**ОДУ'МАТЬСЯ** *сов.* — акылга килү, карашын үзгәртү; уеннан, фикереннән кайту.
**ОДУ'МЫВАТЬСЯ** *несов.* — к. одуматься.
**ОДУРА'ЧИВАТЬ** *несов. разг.*— к. одурачить.
**ОДУРА'ЧИВАТЬСЯ** *несов. страд. разг.*— алдап көлкегә калдырылу, төпсез чанага утыртылу.
**ОДУРА'ЧИТЬ** *сов. разг.*— алдап көлкегә калдыру, төпсез чанага утырту.
**ОДУРЕ'ЛЫЙ** *разг.*— юләрләнгән, исәрләнгән, шашкан.
**ОДУРЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *разг.*— баш кату, миңгерәүләнү.
**ОДУРЕ'ТЬ** *сов. разг.*— тилерү, юләрләнү, котыру, шашу.
**ОДУРМА'НИВАТЬ** *несов.* — исертү, тилертү, агулау, томалау, башын әйләндерү, алдау.
**ОДУРМА'НИВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. одурманиться; 2. *страд.* исертелү, агулану, алдану.
**ОДУРМА'НИТЬ** *сов.*— к. одурманивать.
**ОДУРМА'НИТЬСЯ** *сов.*— исерү, агулану, алдану, баш әйләнү.
**О'ДУРЬ** *ж. мн.* нет, *разг.*— миңгерәү, миңгерәүләнү, башы томалану; *сонная одурь*— йокыдан миңгерәүләнү.
**ОДУРЯ'ТЬ** *несов.* — миңгерәүләндерү, исертү.
**ОДУТЛОВА'ТОСТЬ** *ж. мн.* нет — шешенгәнлек; *одутловатость лица* — битнең шешенгәнлеге.
**ОДУТЛОВА'ТЫЙ** — кабарынкы, күперенке, шешенгәнсыман.
**ОДУ'ТЛОСТЬ** *ж. мн.* нет, *устар.*— к. одутловатость.
**ОДУ'ТЛЫЙ** *устар.* — к. одутловатый.
**ОДУХОТВОРИ'ТЬ** *сов.* — 1. аңлы дип тану, илаһи көч дип тану (борынгы кешеләрнең табигатьне һәм хайваннар дөньясын аңлы дип танулары); 2. *(воодушевить)* дәртләндерү, рухын күтәрү, дәрт кертү, илһам бирү, рух бирү.
**ОДУХОТВОРИ'ТЬСЯ** *сов. книж.*— дәртләнү, рухлану.
**ОДУШЕВИ'ТЬ** *сов. книж.*— 1. җанлы дип тану; *одушевить природу* — табигатьне җанлы дип тану (борынгы, кыргый кешеләр уйлавынча); 2. рухын күтәрү, рухландыру, дәртләндерү; *одушевить массы идеей борьбы* — массаларны көрәш идеясе белән рухландыру.
**ОДУШЕВИ'ТЬСЯ** *сов. книж.*— рухлану, дәртләнү.
**ОДУШЕВЛЁННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— җанлылык.
**ОДУШЕВЛЁННЫЙ** *книж.* — 1. җанлы, җанландырылган; 2. *только полн. формы* күтәренке рухлы.
**ОДУШЕВЛЯ'ТЬ** *несов. книж.*— к. одушевить.
**ОДУШЕВЛЯ'ТЬСЯ** *несов. книж.*— 1. к. одушевиться; 2. *страд.* җанлы дип танылу, рухландырылу, дәртләндерелү.
**ОДЫ'ШКА** *ж. мн.* нет — тын бетү, тын кысылу; күкрәк кысу, сулыш кысылу.
**ОЕВРОПЕ'ИВАТЬСЯ** *несов.* — к. оевропеиться.
**ОЕВРОПЕ'ИТЬСЯ** *сов.*— европалашу.
**ОЖЕЛЕ'ДЬ** *ж. обл. спец.*— к. гололедица.
**ОЖЕНИ'ТЬ** *сов. устар. обл.*— к. женить.
**ОЖЕНИ'ТЬСЯ** *сов. устар. обл.*— к. жениться.
**ОЖЕРЕБИ'ТЬ** *сов. просторечь.*— колынлау, колын китерү.
**ОЖЕРЕБИ'ТЬСЯ** *сов.*— колынлау.
**ОЖЕРЕ'ЛЬЕ** *ср.* — муенса.
**ОЖЕСТОЧА'ТЬ** *несов. книж.* — к. ожесточить.
**ОЖЕСТОЧА'ТЬСЯ** *несов. книж.*— 1. к. ожесточиться; 2. *страд.* усалландырылу, рәхимсезләндерелү.
**ОЖЕСТОЧЁННЫЙ** *книж.* — каты, явыз, рәхимсез, аяусыз; *ожесточённая борьба* — каты көрәш, аяусыз көрәш.
**ОЖЕСТОЧИ'ТЬ** *сов. книж.*— 1. *(сделать жестоким)* шәфкатьсезләндерү, усалландыру, рәхимсезләндерү, аяусызландыру; 2. *(озлобить)* ачуын китерү, усалландыру; 3. *(сделать упорным)* киреләндерү, килешмәүчән итү.
**ОЖЕСТОЧИ'ТЬСЯ** *сов. книж.* — 1. *(стать жестоким)* рәхимсезләнү, аяусызлану, шәфкатьсезләнү; 2. *(озлобиться)* ачу килү, усаллану; 3. *(стать упорным)* киреләнү, тискәреләнү, үз сүзләнү.
**ОЖЕ'ЧЬ** *сов.*— 1. к. обжечь 2; 2. *перен. разг.* сыдыру (чыбыркы, камчы һ. б.

белән); *ожечь кнутом* — чыбыркы белән сыдыру.

**ОЖЕ'ЧЬСЯ** *сов.* — к. обжечься.

**ОЖИВА'ТЬ** *несов.* — к. ожить.

**ОЖИВИ'ТЬ** *сов.* — 1. *(возвратить к жизни)* терелтү; 2. *перен.* дәртләндерү, җанландыру, рухны күтәрү, дәртләндереп җибәрү, җанландырып җибәрү; *весна оживила его* — яз аны дәртләндереп җибәрде; *оживить работу кружка* — түгәрәкнең эшен җанландыру; 3. *перен.* җанландыру, ачыграк төс кертү, ачыграк төс бирү, төсен ачу; яктыртып җибәрү; *улыбка оживила его лицо* — елмаю аның чыраен яктыртып җибәрде.

**ОЖИВИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. *только ед.* терелү, җанлану; 2. *перен.* яңадан дәртләнеп китү, җанланып китү, рухланып китү; 3. *перен.* ачыграк төс алу, яктырып китү; *лицо оживилось* — йөзе яктырып китте.

**ОЖИ'ВКА** *ж. спец.* — 1. *только ед. (действие)* к. оживить 3; 2. химчистка аркылы үткәрү (тукымаларның төсен ачыклау өчен).

**ОЖИВЛЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — 1. *(действие)* к. оживить; 2. *(состояние)* к. оживиться.

**ОЖИВЛЁННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — җанлылык, күңеллелек.

**ОЖИВЛЁННЫЙ** — җанлы, күңеле күтәренке, шатлыклы, рухлы, дәртле, кызу; *оживлённая дискуссия* — кызу дискуссия, кызу бәхәс.

**ОЖИВЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. оживить.

**ОЖИВЛЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. оживиться; 2. *страд.* терелтелү; дәртләндерелү, рухландырылу.

**ОЖИВОТВОРИ'ТЬ** *сов. книж. устар.* — к. животворить.

**ОЖИВОТВОРЯ'ТЬ** *несов. книж. устар.* — к. животворить.

**ОЖИГА'ТЬ** *несов.* — к. ожечь.

**ОЖИГА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. ожечься; 2. *страд.* пешерелү, яндырып алыну.

**ОЖИДА'ЛКА** *ж. простореч.* — к. ожидальня.

**ОЖИДА'ЛЬНЯ** *ж. разг.* — көтеп тору бүлмәсе.

**ОЖИДА'НИЕ** *ср.* — 1. *(действие)* к. ожидать; 2. *чаще мн. (надежда)* өмет. ◇ В ожидании *эвф. (о женщине)* — бала көтү, бала табарга хәзерләнү.

**ОЖИДА'ТЬ** *несов. книж.* — көтү, көтеп тору.

**ОЖИЖИ'ТЕЛЬ** *м. спец.* — сыеклаткыч (газсыман булган матдәләрне сыеклык хәленә китерү приборы).

**ОЖИ'МОК** *м.* — к. обжимок.

**ОЖИ'НОК** *м. обл.* — к. обжинок.

**ОЖИРЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — симерү, май каплау, май басу; *ожирение сердца* — йөрәкне май каплау, йөрәкне май басу.

**ОЖИРЕ'ТЬ** *сов.* — симерү.

**ОРДА'** *ж.* — 1. урда (а. *истор.* берничә күчмә төрки кабиләләренең дәүләт берләшмәсе; б. *истор.* борынгы Россиядә монгол-татарларның гаскәрләре); *Золотая Орда* — Алтын Урда; 2. *перен. презрит.* тәртипсез халык төркеме, юлбасарлар, банда; *разгром фашистских орд* — фашист юлбасарларын тар-мар итү.

**ОРДА'ЛИЯ** *ж. истор.* — ордалия (гаепләнүче кешене газаплап сынау).

**О'РДЕН** I *м.* — орден (сугышта яки социалистик төзелештә зур хезмәт күрсәткән өчен бирелә торган билге); *орден Ленина* — Ленин ордены; *орден Трудового Красного Знамени* — Хезмәт Кызыл Байрак ордены; *орден Отечественной войны* — Ватан сугышы ордены; *орден Суворова* — Суворов ордены; *орден Кутузова* — Кутузов ордены; *орден Красной Звезды* — Кызыл Йолдыз ордены; *орден „Знак почета"* — „Почет билгесе" ордены; *орден Славы* — Дан ордены; *орден „Мать-героиня"* — „Герой ана" ордены; *орден „Материнская слава"* — „Ана даны" ордены; *наградить орденом* — орден белән бүләкләү; *получить орден* — орден алу; *кавалер ордена* — орден кавалеры.

**О'РДЕН** II *м. истор.* — орден (урта гасырларда монахларның яки руханиларның, рыцарьларның махсус оешмасы); *орден иезуитов* — иезуитлар ордены.

**ОРДЕНОНО'СЕЦ** *м.* — орден алган, орденлы; *артист-орденоносец* — орденлы артист.

**ОРДЕНОНО'СНЫЙ** — орденлы; *орденоносный завод* — орденлы завод.

**О'РДЕНСКИЙ** — орден...-ы; *орденская лента* — орден тасмасы.

**О'РДЕР** I *м.* — ордер; *ордер на квартиру* — квартира алу ордеры.

**О'РДЕР** II *м. архит.* — ордер (архитектурада композициянең бер төре).

**ОРДИНА'Р** *м. мн.* нет, *спец.* — ординар (елга яки күл суының берничә ел эчендәге уртача биеклеге).

**ОРДИНА'РЕЦ** *м. воен.* — ординарец (командирның йомышларын үтәүче гаскәри хезмәткәр).

**ОРДИНА'РНЫЙ** *книж.* — 1. (*заурядный*) гади, еш очрый торган; *ординарный человек* — гади кеше; *ординарный случай* — еш очрый торган хәл; 2. *офиц. доревол.* штаттагы; *ординарный профессор* — штаттагы профессор.

**ОРДИНА'ТА** *ж. мат.* — ордината (аналитик геометриянең координаталар системасындагы перпендикулярның бер төре).

**ОРДИНА'ТОР** *м. офиц.* — ординатор (больницаның берәр бүлеге яки палатасы белән идарә итүче врач).

**ОРДИНАТУ'РА** *ж. офиц.* — ординатура (1. ординаторлык вазифасы; 2. практик медицина аспирантурасының бер төре; 3. *устар.* штаттагы профессорлык вазифасы).

**ОРДЫ'НЕЦ** *м. истор.* — 1. урдачы (а. Алтын Урда кешесе; б. Алтын Урдадан түләп алынган яки пленнан качкан кеше); 2. мирза (Алтын Урдадан патша хезмәтенә күчкән кеше); 3. ат токымы.

**ОРДЫ'НСКИЙ** *истор.* — урда...-ы; *ордынский человек* — урда кешесе.

**ОРДЫ'НЩИНА** *ж. истор.* — салым (алтын урдалылар тарафыннан рус җирләренә салынган салым).

**ОРЁЛ** *м.* — 1. каракош, бөркет; 2. *перен.* көчле, зирәк, сизгер, талантлы кеше; 3. *дореβол.* Россия гербы (ике башлы сәмруг кош). ◇ **Орёл или решка?** — иләкме, күнме? **Римские орлы** *истор.* — рим легионнарының байраклары (көмештән ясалып, озын сапка утыртылган сәмруг-кош рәсеме).

**ОРЕО'Л** *м. книж.* — 1. *ритор.* ореол, нур, нурга күмелгәнлек, хөрмәт, дан; *в ореоле славы* — дан нурында, данга күмелгән; 2. *фот. (световая кайма)* яктылык каймасы; 3. *спец.* яктылык, ялкын, нур; *ореол над пламенем лампы* — лампа уты өстендәге яктылык.

**ОРЕ'Х** *м.* — 1. чикләвек; *кедровый орех* — эрбет чикләвеге; 2. *только ед.* чикләвек агачы; *шкаф из ореха* — чикләвек агачыннан ясалган шкаф; 3. *горн. (сорт антрацита)* чикләвексыман антрацит. ◇ **Разделать под орех** *перен. разг. шутл.* — 1. бик шәп итеп эшләү; 2. бик нык тиргәү, арт сабагын укыту. **Будет тебе на орехи** *разг. шутл.* — кирәгенне бирерләр.

**ОРЕ'ХОВКА** *ж. зоол.* — чикләвек чыпчыгы.

**ОРЕ'ХОВЫЙ** — 1. чикләвек...-ы; *ореховая скорлупа* — чикләвек кабыгы; 2. чикләвек агачыннан ясалган; *ореховая мебель* — чикләвек агачыннан ясалган мебель; 3. чикләвекле; *ореховый торт* — чикләвекле торт.

**ОРЕ'ШЕК** *м. уменьш.* — к. орех.

**ОРЕ'ШИНА** *ж. мн.* нет, *спец. обл.* — к. орешник 2.

**ОРЕ'ШНИК** *м. мн.* нет — 1. чикләвек агачы; 2. чикләвек куаклыгы; 3. *горн.* к. орех 3.

**ОРЕ'ШНИКОВЫЙ** — чикләвек...-ы; *орешниковая поросль* — чикләвек үсентесе.

**ОРИГИНА'Л** *м.* — 1. төп нөсхә, оригинал; *оригинал рукописи* — кулъязманың төп нөсхәсе; 2. *разг. (чудак, странный человек)* кызык кеше, сәер кеше, мәзәк кеше, гаҗәп кеше; *мало ли какие оригиналы бывают* (А. Островский) — дөньяда сәер кешеләр азмыни.

**ОРИГИНА'ЛЬНИЧАТЬ** *несов. разг. неодобр.* — үзенчә кылану (кешедә булмаган кыланышлар белән үзенә игътибар иттерергә азаплану).

**ОРИГИНА'ЛЬНО** *нареч.* — оригиналь рәвештә, бүтәннәргә охшамаган итеп, үзенә бер төрле итеп; *оригинально одеваться* — үзенә бер төрле итеп киенү.

**ОРИГИНА'ЛЬНОСТЬ** *ж. книж.* — 1. оригинальлек, төп нөсхә булу, оригиналь булу; *оригинальность рукописи заподозрена* — кулъязманың төп нөсхә булуы шик тудырган; 2. оригиналь булу, үзенә бер төрле булу; *оригинальность костюма* — костюмның оригиналь булуы.

**ОРИГИНА'ЛЬНЫЙ** *книж.* — 1. оригиналь, төп; *оригинальные рукописи Л. Толстого* — Л. Толстойның төп кулъязмалары; 2. оригиналь, үзенә бер төрле, башкаларга охшамаган, үзенә генә хас; *оригинальные взгляды* — оригиналь карашлар; *оригинальная красота* — үзенә бер төрле матурлык.

**ОРИЕНТАЛИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *книж.* — ориентализм (1. көнчыгыш халыкларының телләрен һәм гомумән культураларын тикшерү, өйрәнү; 2. көнчыгыш элементларының чагылышы (музыкада, стильдә һ. б.).

**ОРИЕНТАЛИ'СТ** *м.* — ориенталист (көнчыгыш халыклары телләренең һәм культураларының белгече).

**ОРИЕНТА'ЛЬНЫЙ** *книж.* — ориенталь, көнчыгыш...-ы; *ориентальный стиль в изобразительном искусстве* — сынлы сәнгатьтә ориенталь стиль.

**ОРИЕНТА'ЦИЯ** *ж. книж.* — 1. *только ед. (действие)* к. ориентировать, ориентироваться; 2. *только ед. перен.* хәбәрдар булу, белү, таныш булу; *хорошая ориентация в новейшей исторической литературе* — иң яңа тарихи әдәбият белән яхшы таныш булу; 3. ориентация тоту, исәп тоту, өмет баглау, юнәлеш алу; *среди передовой интеллигенции Запада крепнет ориентация на Советский Союз* — Көнбатыштагы алдынгы интеллигенция арасында Советлар Союзына ориентация тоту көчәя; 4. күздә тоту; *ориентация на массового читателя* — массовый укучыны күздә тоту.

**ОРИЕНТИ'Р** *м.* — 1 *спец.* ориентир (а. күрсәткеч прибор; б. *воен.* бер урынны яхшы белергә, танышырга, истә калдырырга ярдәм итә торган характерлы әйбер); *ветряная мельница может служить хорошим ориентиром* — җил тегермәне яхшы ориентир булып хезмәт итә ала; 2. *перен.* юнәлеш; *выбрать правильный ориентир* — дөрес юнәлеш алу.

**ОРИЕНТИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.* — 1. төшендерү, таныштыру; *вы недостаточно ориентировали его в этом вопросе* — сез аны бу мәсьәлә белән җитәрлек дәрәҗәдә таныштырмагансыз; 2. *книж.* юнәлдерү, юнәлеш бирү; *ориентировать исследование на практические задачи социалистического строительства* — тикшеренү эшләрен социализм төзелешенең практик бурычларына юнәлдерү; 3. *книж.* күздә тоту; *ориентировать книги на широкого читателя* — китапларны укучыларның киң массасын күздә тотып чыгару.

**ОРИЕНТИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов.* — 1. юлны җиңел табу; юнәлеш ала белү, җаена төшенү, үзең торган урынны билгеләү, дөрес аңлау; *он хорошо ориенти-*

*руется в лесу* — ул урманда юлны җиңел таба; 2. танышу, ияләшү; *он уже ориентировался в делопроизводстве* — канцелярия эшләрен алып бару белән ул танышкан инде; 3. күздә тоту, исәпкә алу; *ориентироваться на рабочую аудиторию* — эшчеләр аудиториясен күздә тоту; 4. *страд.* юнәлеш бирелү, юнәлдерелү; *самолёты ориентируются радиосигналами* — самолётларга радиосигналлар белән юнәлеш бирелә.

**ОРИЕНТИРО'ВКА** *ж.* — к. ориентация.

**ОРИЕНТИРО'ВОЧНО** *нареч.* — чама белән, чама белән әйткәндә; *это обойдётся ориентировочно в тысячу рублей* — чама белән әйткәндә бу мең сумга төшәр.

**ОРИЕНТИРО'ВОЧНЫЙ** — 1. танышу өчен...; *ориентировочный полёт* — танышу өчен очу; 2. якынча..., чамалы; *ориентировочный подсчёт* — якынча исәп.

**ОРКЕ'СТР** *м.* — оркестр (1. музыкаль инструментларның ансамбле; *симфонический оркестр* — симфоник оркестр; *струнный оркестр* — кыллы оркестр; 2. инструменталь музыканы башкаручылар коллективы; 3. оркестрда уйнаучылар бүлмәсе).

**ОРКЕСТРА'НТ** *м.*, **ОРКЕСТРАН'ТКА** *ж.* — оркестрант (оркестрда уйнаучы).

**ОРКЕСТРА'НТСКИЙ** — оркестрант...-ы, оркестрантлар...-ы; *оркестрантская комната* — оркестрантлар бүлмәсе.

**ОРКЕСТРИО'Н** *м.* *муз.* — оркестрион (орга́нның бер төре).

**ОРКЕСТРОВА'ТЬ** *сов.* и *несов.* *муз.* — оркестрга салу, оркестровать итү.

**ОРКЕСТРОВА'ТЬСЯ** *несов. страд. муз.* — оркестрга салыну, оркестровать ителү.

**ОРКЕСТРО'ВКА** *ж.* *мн.* нет, *муз.* — к. оркестровать.

**ОРКЕСТРО'ВЫЙ** — оркестр...-ы, оркестр өчен язылган; *оркестровая партия* — оркестр партиясе (музыкаль әсәрнең оркестр башкара торган өлеше); *оркестровая музыка* — оркестр өчен язылган музыка.

**ОРЛА'Н** *м. зоол.* — диңгез бөркете.

**ОРЛЁНОК** *м.* (мн. орля́та) — яшь бөркет, каракош баласы.

**О'РЛИЙ** *редко* — бөркет...-ы; *орлий глаз* — бөркет күзе.

**О'РЛИК** *м.* — 1. кечкенә бөркет; 2. *бот.* (*водосбор*) күгәрчен чәчәге.

**ОРЛИ'НЫЙ** — 1. бөркет...-ы; *орлиное крыло* — бөркет канаты; 2. *перен.* батыр, гайрәтле, кыю; *орлиный взгляд* — батыр караш, кыю караш. ◇ **Орлиный нос** *перен.* — кәкре борын.

**ОРЛИ'ЦА** *ж.* *зоол.* — ана бөркет, ана каракош.

**ОРЛЯ'К** *м. бот.* — кара абага.

**ОРЛЯ'НКА** *ж.* *мн.* нет — акча чөю уены.

**ОРНА'МЕНТ** *м.* — 1. орнамент (төрле формадагы график яки скульптур бизәкләр); 2. *муз.* (*украшение мелодии*) көй бизәкләре, музыкаль бизәкләр.

**ОРНАМЕНТА'ЛЬНЫЙ** — 1. *спец.* орнамент...-ы, орнамент ясау...-ы; *орнаментальные работы* — орнамент ясау эшләре; 2. *искус.* *лит.* орнаментлы, орнаментка бай, артык бизәкле; *орнаментальный стиль* — орнаментлы стиль.

**ОРНАМЕНТА'ЦИЯ** *ж.* *мн.* нет, *искус.* — 1. к. орнаментировать; 2. (*система орнаментов*) орнаментлар системасы.

**ОРНАМЕНТИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.* *искус.* — орнаментлау, бизәкләү, бизәк төшерү; *орнаментировать купол* — гөмбәзне орнаментлау; *орнаментировать рукопись* — кулъязманы бизәкләү.

**ОРНАМЕНТИ'РОВАТЬСЯ** *несов.* *страд.* *искус.* — орнаментлану, бизәклөнү, бизәк төшерелү.

**ОРНАМЕНТОВА'ТЬ** *сов.* и *несов.* *искус.* — к. орнаментировать.

**ОРНАМЕНТОВА'ТЬСЯ** *несов.* *искус.* — к. орнаментироваться.

**ОРНИТО'ЛОГ** *м.* — орнитолог (орнитология белгече).

**ОРНИТОЛОГИ'ЧЕСКИЙ** *зоол.* — орнитология...-ы, орнитологик; *орнитологическая станция* — орнитологик станция.

**ОРНИТОЛО'ГИЯ** *ж.* *зоол.* — орнитология (зоологиянең кошларны өйрәнә торган бүлеге).

**ОРОБЕ'ЛЫЙ** *разг.* — каушаган, каушап калган, калтыраган; *оробелые руки* — калтыраган куллар.

**ОРОБЕ'ТЬ** *сов.* *разг.* — каушап китү, каушап калу, куркып китү, куркуга төшү; *от чего же вы не говорите?* — *оробел* — ни өчен сез сөйләшмисез? — каушап киттем.

**ОРОГОВЕ'ТЬ** *сов. спец.* — мөгезләнү (тиренең тышкы катлавы сизү сәләтен югалту).

**ОРОГРАФИ'ЧЕСКИЙ** *геогр.* — орография...-ы, орографик; *орографический кабинет* — орография кабинеты.

**ОРОГРА'ФИЯ** *ж.* — орография (физик географиянең җир өсте рельефын өйрәнә торган бүлеге).

**ОРОСИ'ТЕЛЬНЫЙ** *спец.* — сугару...-ы; *оросительные работы* — сугару эшләре.

**ОРОСИ'ТЬ** *сов.* — 1. *книж.* чылату, дымландыру, юешләндерү; *дождь оросил землю* — яңгыр җирне дымландырды; 2. сугару; *оросить поля* — басуларны сугару; 3. *мед.* дезинфекцияләү.

**ОРОСИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. чылану, дымлану, юешләнү; 2. сугарылу.

**ОРОЧО'НЫ** *мн.* — орочоннар, эвенк халкы, эвенклар (Байкал аръягыннан алып Амур өлкәсенең төньяк-көнчыгыш өлешенә кадәр урнашкан көньяк эвенклар группасы; алар үзләрен орочон дип атыйлар).

**ОРОША'ТЬ** *несов.* — к. оросить.

**ОРОША'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. ороситься; 2. *страд.* сугарылу; чылатылу, юешләндерелү.

**ОРОШЕ'НИЕ** *ср.* *мн.* нет — 1. (*действие*) к. оросить; 2. *геогр.* явым-төшем күләме, елгалар ешлыгы.

**ОРТОДО'КС** *м.* *книж.* — ортодокс (ортодоксаль карашлы кеше).

**ОРТОДОКСА'ЛЬНОСТЬ** *ж.* *мн.* нет, *книж.* — ортодоксальлек.

**ОРТОДОКСА'ЛЬНЫЙ** *книж.* — орто-

доксаль (нинди дә булса бер тәгълиматның нигезләренә эзлекле рәвештә таянып эш итүче); *ортодоксальные взгляды* — ортодоксаль карашлар.

**ОРТОДО'КСИЯ** *ж. мн.* нет, *книж.*— ортодоксия (караштa нык эзлеклелек).

**ОРТОПЕДИ'СТ** *м. мед.*— ортопедия белгече.

**ОРТОПЕДИ'ЧЕСКИЙ** *мед.* — ортопедия...-ы, ортопедик; *ортопедический институт* — ортопедия институты; *ортопедическая обувь* — ортопедик аяк киеме.

**ОРТОПЕ'ДИ'Я** *ж. мед.*— ортопедия (хирургиянең бүлеге: гәүдә һәм кул-аякларның кәкрәюен дәвалау белән шөгыльләнә).

**ОРУ'ДИЕ** *ср.*—1. корал; *орудие труда* — хезмәт коралы; 2. *перен.* (*средство*) чара, юл; 3. *воен.* (*пушка*) туп, орудие.

**ОРУДИ'ЙНЫЙ** *воен.* — орудие...-ы, туп...-ы; орудиеләрдән..., туплардан...; *орудийный огонь* — орудиеләр уты; *открыть орудийный огонь* — орудиеләрдән ут ачу.

**ОРУ'ДНЫЙ** 1. —*устар.* к. **орудийный**; 2. органик; *орудные тела* — органик җисемнәр; 3. *грам.* кораллык...-ы; *орудное значение творительного падежа* — творительный падежның кораллык мәгънәсе.

**ОРУ'ДОВАТЬ** *несов. разг.*—1. эшләү, эш итү, эш итә белү (берәр корал белән); *ловко орудовать пилой* — пычкы белән оста эш итү; 2. *преимущ. отрицат.* кемгә дә булса, каршы эш алып бару; 3. *перен. неодобр.* актару, айкау, айкап йөрү; *он орудует всеми делами* — ул бөтен эшләрне актара.

**ОРУЖЕ'ЙНИК** *м.*— мылтык остасы, корал остасы.

**ОРУЖЕ'ЙНЫЙ** — корал...-ы; *оружейный завод* — корал заводы. ◇ **Оружейная палата** — Мәскәү Кремлендәге борынгы кораллар музее.

**ОРУЖЕНО'СЕЦ** *м.* — 1. *истор.* корал йөртүче (рыцарьның коралын йөртүче); 2. *перен. ирон.* сукырларча ышанган кеше.

**ОРУ'ЖИЕ** *ср.* — корал; *защищаться с оружием в руках* — корал тотып саклану; *печать — могучее оружие в классовой борьбе* — матбугат — сыйнфый көрәштә бик көчле корал. ◇ **Бряцать оружием** — корал белән куркыту, сугыш коткысы тарату, корал белән янау. **Призывать к оружию** — кораллы көрәшкә чакыру, коралланугa чакыру. **Сложить оружие** — корал ташлау. **Поднять оружие** *ритор.*—1. сугыш башлау, сугыш ачу; 2. коралланып баш күтәрү. **Товарищ по оружию** — коралдаш, (армиядә бергә хезмәт иткән кеше).

**ОРУ'Н** *м.*, **ОРУ'НЬЯ** *ж. простореч.*— акыручы, бакыручы.

**ОРФОГРАФИ'ЧЕСКИЙ**—орфография...-ы, орфографик; *орфографические правила* — орфография кагыйдәләре; *орфографический словарь* — орфографик сүзлек.

**ОРФОГРА'ФИЯ** *ж.*— орфография, дөрес язу кагыйдәләре.

**ОРФОЭПИ'ЧЕСКИЙ** *лингв.* — орфоэпия...-ы, орфоэпик; *орфоэпические нормы* — орфоэпик нормалар; *орфоэпические правила* — орфоэпия кагыйдәләре.

**ОРФОЭ'ПИЯ** *ж. лингв.*—орфоэпия (дөрес әйтү кагыйдәләре; сүзләрне орфоэпия кагыйдәләре буенча җиренә җиткереп әйтү).

**ОРХИДЕ'Я** *ж. бот.*— күке яше (тропик үсемлек һәм аның чәчәге).

**ОРША'Д** *м.* — ширбәт (шикәрле миндаль сөте).

**ОРЯ'СИНА** *ж. простореч.*—1. (*большая палка, дубина*) күсәк, колга; 2. *бран. пренебр.* күсәк (килбәтсез озын кеше).

**ОСА'** *ж. зоол.*— шөпшә, сагызак.

**ОСА'ДА** *ж.*—1. *воен.* камау, камап алу, чолгау, чолгап алу; *осада города* — шәһәрне камап алу; 2. камап алыну; *войска находились в осаде* — гаскәрләр камап алынган иде.

**ОСАДИ'ТЬ** *сов.*—1. камау, чолгау, камап алу, чолгап алу; *толпа осадила здание* — бер төркем халык бинаны камап алды; 2. *перен.* теңкәгә тию, йөдәтү, йөдәтеп бетерү; *его осадили заявлениями* — аны гаризалар белән йөдәтеп бетерделәр; 3. (*остановить на всём скаку*) туктату; 4. чигендерү; *осади назад* — артка чигендер; 5. *разг.* (*умерить пыл, оборвать резким замечанием*) тыю, кырт кисеп туктату; 6. *хим.* (*выделить составную часть раствора в виде осадка*) тондыру, төпкә утырту; 7. *устар.* (*сделать оседлым*) утракландыру.

**ОСА'ДКА** *ж. мн.* нет — 1. *спец.* (*действие*) к. **осесть**; 2. *тех.* утыру тирәнлеге (суда утыру тирәнлеге); *судно с небольшой осадкой* — суда утыру тирәнлеге зур булмаган судно; 3. *тех.* утырту (чүкеп әйбернең озынлыгын киметеп, аркылы кисемен арттыру).

**ОСА'ДКИ** *только мн.*— явымнар, явым-төшем.

**ОСА'ДНЫЙ**—1. камау...-ы; *осадная артиллерия* — камау артиллериясе; 2. *устар.* к. **оборонительный**. ◇ **Осадное положение** *офиц.* — хәрби хәл (сугыш вакытында тылда тәртип саклау өчен күрелгән чиктән тыш чаралар).

**ОСА'ДОК** *м.*—1. утырма, юшкын; *вода дала осадок* — суның юшкыны утырган; 2. *перен.* авыр тәэсир, эз; *в душе остался неприятный осадок* — йөрәктә күңелсез эз калды; 3. *геол.* (*осадочные породы*) утырма токымнар.

**ОСА'ДОЧНЫЙ** *геол.*— утырма...ы; *осадочные горные породы* — утырма тау токымнары.

**ОСАЖДА'ТЬ** *несов.*— к. **осадить** 1, 2, 6.

**ОСАЖДА'ТЬСЯ** *несов.*—1. *книж.* төпкә утыру; *соль осаждается на дно* — тоз төпкә утыра; 2. *книж.* явым-төшем; *испарения осаждаются в виде дождя* — парлар янгыр булып явалар; 3. *страд.* камап алыну; артка чигендерелү; туктатылу; төпкә утыртылу.

**ОСАЖДЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет —1. *хим.* төпкә утыру; 2. яву.

**ОСА'ЖИВАТЬ** *несов.*—1. туктату, чигендерү; 2. тыю, кырт кисеп туктату.

**ОСА'ЖИВАТЬСЯ** *несов.*—1. *страд.* туктатылу, чигендерелү; тыелу, кырт кисеп туктатылу; 2. *простореч.* к. осаждаться.

**ОСА'ЛИТЬ** *сов.*— әбәкләү (төрле уеннарда).

**ОСА'НИСТЫЙ** — мәһабәт, мәһабәт кыяфәтле; *человек он был собою видный, осанистый* — ул күренекле, мәһабәт кыяфәтле кеше иде.

**ОСА'НКА** *ж. мн.* нет — кыяфәт, тышкы күренеш, матур кыяфәт, мәһабәтлелек, килешле сын-сыйфат, сын-гәүдә торышының матурлыгы.

**ОСА'ННА** *ж. мн.* нет, *церк.*: петь осанну —1. *перен. книж. устар.* күккә күтәрү, мәдхия җырлау; 2. *перен. устар.* ихлас күңелдән бирелү, ышану, буйсыну.

**ОСАТАНЕ'ЛЫЙ** *разг.*— явыз, явызланган, җенләнгән, котырган.

**ОСАТАНЕ'ТЬ** *сов. разг.*—1. явызлану, җенләнү, котыру, бик каты ачу килү; 2. нәфрәт тудыру, туйдырып бетерү, биздерү.

**ОСВА'ИВАТЬ** *несов.*— к. освоить.

**ОСВА'ИВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. освоиться; 2. *страд.* үзләштерелү.

**ОСВЕДОМИ'ТЕЛЬ** *м.*— белдерүче, хәбәр бирүче, хәбәр итүче, белдереп торучы.

**ОСВЕДОМИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.*— белдерү ...-ы, таныштыру...-ы; *речь носила чисто осведомительный характер* — речь бары тик таныштыру характерында гына иде.

**ОСВЕ'ДОМИТЬ** *сов. книж.*— хәбәр итү, белдерү, таныштыру.

**ОСВЕ'ДОМИТЬСЯ** *сов.*— сорашу, белешү, сорашып белү.

**ОСВЕДОМЛЁННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — хәбәрдарлык.

**ОСВЕДОМЛЁННЫЙ** — хәбәрдар, таныш, белә торган; *осведомленный человек* —хәбәрләр кеше.

**ОСВЕДОМЛЯ'ТЬ** *несов.*— к. осведомить.

**ОСВЕДОМЛЯ'ТЬСЯ** *несов.*—1. к. осведомиться; 2. *страд.* хәбәр ителү, белдерелү, таныштырылу.

**ОСВЕЖА'ТЬ** *несов.*— к. освежить.

**ОСВЕЖА'ТЬСЯ** *несов.*—1. к освежиться; 2. *страд.* сафландырылу, җилләтелү; ачыкландырылу; искә төшерелү; яңартылу.

**ОСВЕЖЕВА'ТЬ** *сов. спец.*— тиресен тунау, эчен арчу, эчен алу (суелган терлекнең).

**ОСВЕЖИ'ТЕЛЬНЫЙ** — җиңеләйтеп җибәрә торган, хәл кертә торган; *освежительный ветер* — җиңеләйтеп җибәрә торган җил; *освежительные напитки* — хәл кертә торган эчемлекләр.

**ОСВЕЖИ'ТЬ** *сов.*—1. сафландыру, җилләтү, алмаштыру (һаваны); *освежить воздух* — һаваны сафландыру, һаваны алмаштыру; 2. ачыкландыру; *освежить краски в картине* — картинаның буяуларын ачыкландыру; 3. әйбәтләндерү, көч кертү, яшәртеп җибәрү, тазарту, тазартып җибәрү; ныгыту; *поездка на пароходе освежила его* — пароходта йөрү аны әйбәтләндереп җибәргән; 4. искә төшерү, хәтергә төшерү; *освежить воспоминания детства* — бала-чак истәлекләрен хәтергә төшерү; 5. *разг.* яңарту; *освежить состав комиссии* — комиссия составын яңарту.

**ОСВЕЖИ'ТЬСЯ** *сов.*—1. һава алмаштыру; *я вышел освежиться* — мин һава алмаштырырга чыктым; 2. җиңеләю; *сходи в баню, освежись немного* — мунчага бар, җиңеләеп чык бераз; 3. биткә одеколон сибү, биткә одеколон сөртү; *после бритья он освежился одеколоном* — кырынгач ул битенә одеколон сөртте.

**ОСВЕТИ'ТЕЛЬ** *м. спец.* — яктыртучы (театрда яктылык бирү, яктылык эффектлары ясау эшләрен башкаручы).

**ОСВЕТИ'ТЕЛЬНЫЙ** *спец.*— яктырту...-ы, яктылык бирү ...-ы; *осветительные приборы* — яктырту приборлары; *осветительная сеть* — яктылык бирү челтәре.

**ОСВЕТИ'ТЬ** *сов.*—1. *(сделать светлым)* яктырту; 2. *перен.* аңлатып бирү, сөйләп бирү, яктырту; *осветить положение дела* — эшнең торышын аңлатып бирү, эшнең торышын яктырту.

**ОСВЕТИ'ТЬСЯ** *сов.*— яктыру, яктырып китү, балку, балкып китү; *зал вдруг осветился тысячами огней* — зал көтмәгәндә меңләгән утлар белән балкып китте.

**ОСВЕТЛИ'ТЬ** *сов. спец.* — тонықландыру; *осветлить воду* — суны тонықландыру.

**ОСВЕТЛЯ'ТЬ** *несов. спец.*— к. осветлить.

**ОСВЕЩА'ТЬ** *несов.*— к. осветить.

**ОСВЕЩА'ТЬСЯ** *несов.*—1. к. осветиться; 2. *страд.* яктыртылу, аңлатып бирелү, сөйләп бирелү.

**ОСВЕЩЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет —1. (*действие*) к. осветить; 2. *живоп.* яктыртылыш (картинада бүләгә һәм яктылыкның бүленеше); *неверное освещение* — ялгыш яктыртылыш; 3. *перен.* аңлатып бирү, яктырту; *правильное освещение вопроса* — мәсьәләне дөрес аңлатып бирү; 4. яктыртылу, яктылык; *вечернее освещение комнаты* — бүлмәнең кичке яктыртылуы.

**ОСВЕЩЁННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *тех.*— яктыртылганлык, яктылык дәрәҗәсе, яктыртылу.

**ОСВИДЕ'ТЕЛЬСТВОВАТЬ** *сов. книж.*— карап тикшереп чыгу; *освидетельствовать состояние котлов* — казаннарның торышын (ни хәлдә икәнен) карап тикшереп чыгу. ◇ Освидетельствовать больного — авыруны карау.

**ОСВИНЦЕВА'ТЬ** *сов. тех.*—1. *устар.* (*выделить из руды серебро при помощи свинца*) кургашын кушып, рудадан көмешне аеру; 2. (*покрыть слоем свинца*) кургашынлау, кургашын йөгертү.

**ОСВИНЦО'ВЫВАТЬ** *несов тех.* — к. освинцевать.

**ОСВИРЕПЕ'ТЬ** *сов. разг.*— бик каты ачулану, ярсу, ярсып китү, котырыну.

**ОСВИСТА'ТЬ** *сов.*—1. яратмыйча сызгыру, сызгырып сәхнәдән куу; *освистать актёра* — сызгырып артистны сәхнәдән куу; 2. *перен. разг.* мыскыл итү (мыскыл итеп тәнкыйтьләү); *первые литературные выступления Бальзака были освистаны* —

Бальзакның беренче әдәби чыгышлары мыскыл ителгән иде.

**ОСВИ'СТЫВАТЬ** *несов.*— к. освистать.

**ОСВОБОДИ'ТЕЛЬ** *м. книж.*— азат итүче, ирекккә чыгаручы, коткаручы.

**ОСВОБОДИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.* — азатлык ...-ы, ирeклек ...-ы; *освободительное движение* — азатлык хәрәкәте.

**ОСВОБОДИ'ТЬ** *сов.*—1. *(сделать свободным)* азат итү, ирекккә чыгару, коткару; 2. ычкындыру; *освободить руки от верёвок* — кулларны баудан ычкындыру; 3. *офиц.* чыгару, алу; *освободить от должности* — урыныннан чыгару, урыныннан алу; 4. бушату; *освободить ведро* — чиләкне бушату; *освободить квартиру* — квартирны бушату (квартирдан чыгып китү).

**ОСВОБОДИ'ТЬСЯ** *сов.*—1. азат булу, ирекккә чыгу, котылу; *настанет время, когда освободятся все колониальные народы* — килер бер көн, барлык колониаль халыклар азат булыр; 2. бушау; *квартира освободилась* — квартир бушады.

**ОСВОБОЖДА'ТЬ** *несов.*— к. освободить.

**ОСВОБОЖДА'ТЬСЯ** *несов.*—1. к. освободиться; 2. *страд.* азат ителү, ирекккә чыгарылу, коткарылу; бушатылу.

**ОСВО'ИТЬ** *сов.*—1. үзләштерү; *освоить новые методы работы* — эшнең яңа методларын үзләштерү; *освоить правила арифметики* — арифметика кагыйдәләрен үзләштерү; 2. *спец.* күнектерү, иял әштерү; *освоить чужеземные растения* — чит ил үсемлекләрен күнектерү.

**ОСВО'ИТЬСЯ** *сов.*—1. ияләшү; *освоиться в чужом городе* — чит шәһәргә ияләшү; 2. төшенеп житү, үзләштерү, ияләшеп житү; *освоиться со своей работой* — үзенең эшенә төшенеп житү.

**ОСВЯТИ'ТЬ** *сов. книж. ритор.* — хөрмәтләү, кадерләү, хөрмәтләп мәңге онытылмаслык итү.

**ОСВЯЩА'ТЬ** *несов.*— к. освятить.

**ОСВЯЩА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— хөрмәтләнү, изгеләндерелү.

**ОСЕВО'Й** — күчәр...-ы; *осевая линия* — күчәр сызыгы.

**ОСЕДА'ТЬ** *несов.*— к. осесть.

**ОСЕДЛА'ТЬ** *сов.*—1. иярләү; *оседлать коней* — атларны иярләү; 2. атланып утыру; *оседлать стул* — урындыкка атланып утыру; 3. *спец.* сугышып алу; *пехота оседлала важную дорогу* — пехота бик әһәмиятле юлны сугышып алды; 4. *разг. фам. шутл.* үзенә буйсындыру, муенына атлану.

**ОСЕ'ДЛОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — утраклык. ◇ **Черта оседлости** *дореволюц.* — утраклык чиге (патша указы буенча Россиянең көнбатыш районнарында еврейләргә торырга рөхсәт ителгән урыннарның чиге).

**ОСЁДЛЫВАТЬ** *несов.*— к. оседлать 1, 2.

**ОСЕ'ДЛЫЙ**—утрак...; *оседлые племена*— утрак кабиләләр.

**ОСЕ'КА** *ж. обл.*— киртәләнгән көтүлек.

**ОСЕКА'ТЬ** *несов. обл.*— к. осечь.

**ОСЕКА'ТЬСЯ** *несов.*—1. к. осечься; 2. *страд.* кисеп ташлану.

**ОСЁЛ** *м.*—1. ишәк; 2. *перен. бран.* ишәк (аңгыра, миңгерәү; кире кеше, ялкау кеше). ◇ **Буриданов осёл** — буридан ишәге (чиктән тыш икеләнә торган кешегә карата әйтелә).

**ОСЕЛО'К** *м.* — 1. *(точильный камень)* кайрак, беләү; 2. *спец.* сынау ташы (кыйммәтле металларны сынау өчен); 3. *перен. устар.* сынау коралы; *не делай дружбы моей оселком* — минем дуслыкны сынау коралына әйләндермә.

**ОСЕМЕНИ'ТЬ** *сов. биол. с.-х.*— 1. *(о животных)* ясалма рәвештә аталандыру; 2. *(о растениях)* ясалма рәвештә орлыкландыру.

**ОСЕМЕНЯ'ТЬ** *несов.*— к. осеменить.

**ОСЕМЕНЯ'ТЬСЯ** *несов. страд. с.-х.*— 1. *(о животных)* ясалма рәвештә аталандырылу; 2. *(о растениях)* ясалма рәвештә орлыкландырылу.

**ОСЕНИ'ТЬ** *сов.*—1. *поэт. устар.* *(закрыть, покрыть тенью)* күләгәләү, ышыклау; 2. *перен.* дәртләндерү, рухландыру; *пусть осенит вас победоносное знамя великого Ленина* — сезне бөек Ленинның җиңүчән байрагы рухландырсын; 3. *перен.* колачына алу, эченә алу, каплап алу; *природу всю широко осенив, царил покой* (А. К. Толстой) — бөтен табигатьне үзенең киң кочагына алган тынлык хөкем сөрә иде; 4. кинәт башка килү, кинәт искә төшү; *его осенила мысль* — кинәт аның башына уй килде; 5. *книж. устар.* күренү, сизелү, чагылу, чагылып китү; *улыбка осенила лицо старца* — картның йөзендә елмаю чагылып китте.

**ОСЕНИ'ТЬСЯ** *сов. книж. устар.*— каплану, ышыклану.

**ОСЕ'ННИЙ** — көзге, көз...-ы; *осенние полевые работы* — көзге кыр эшләре.

**О'СЕНЬ** *ж.*—1. көз; *настала осень* — көз житте; 2. *перен. книж.* *(увядание, одряхление, приближение конца)* сүнү, шиңү, пәжү, ахыры житү. ◇ **По осени** — көз көне, көзен; *цыплят по осени считают* — чебешләрне көзен саныйлар.

**О'СЕНЬЮ** *нареч.*— көз көне, көзен, көз; *он приехал осенью этого года* — ул быел көзен килде.

**ОСЕНЯ'ТЬ** *несов.*— к. осенить.

**ОСЕНЯ'ТЬСЯ** *несов.*—1. к. осениться; 2. *страд.* күләгәләнү, ышыклану; каплап алыну.

**ОСЕРДИ'ТЬ** *сов. разг.* — ачуландыру, ачуын кабарту, ачуын китерү.

**ОСЕРДИ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— ачулану, ачу килү.

**ОСЕРЕБРИ'ТЬ** *сов.*—1. *поэт.* *(окрасить в серебряный цвет)* көмеш йөгертү, көмеш төскә буяу, көмеш төсенә кертү; 2. *перен. разг.* *(одарить деньгами)* көмешкә күмү (бик күп акча бирү); 3. *поэт.* *(сделать седым)* чәчне агарту, чал кертү.

**ОСЕРЧА'ТЬ** *сов. простореч.*— ачулану, ачуы килү.

**ОСЕ'СТЬ** *сов.*— 1. басылу, иңү; *фундамент осел* — фундамент басылган; *гора осела* — тау иңгән; *дно озера осело* — күл-

вең төбе иңгән; 2. утыру; *на дно стакана осела соль* — стаканның төбенә тоз утырган; 3. куну, утыру; *пыль осела* — тузан кунган; 4. төшү; *туман осел росой* — томан чык булып төшкән; 5. утыру, утрак тормышка күчү; *кочевники осели в долинах рек* — күчмә халыклар елгаларның үзәннәренә утырганнар.

**ОСЕТИ'НКА** *ж.*— осетин хатын-кызы.

**ОСЕТИ'НСКИЙ** — осетин...-ы; *осетинский язык* — осетин теле.

**ОСЕТИ'НЫ** (*ед.* осетин) — осетиннар, осетин халкы (Кавказда яшәүче халык).

**ОСЁТР** *м. зоол.*— осётр, мәрсин балыгы.

**ОСЕТРИ'НА** *ж. мн.* нет — осетрина, осётр ите.

**ОСЕТРИ'ННЫЙ** — к. осетровый.

**ОСЕТРО'ВЫЙ** — осётр...-ы; *осетровая икра* — осётр икрасы.

**ОСЕ'ЧКА** *ж.*— 1. осечка, атылмый калу; *ружьё дало осечку* — мылтык атылмый калды; 2. *перен. разг.* (*промах, неудача при выполнении чего-н.*) ялгышу, мах бирү, эш барып чыкмау.

**ОСЕ'ЧЬ** *сов. обл.*— к. обсечь 1.

**ОСЕ'ЧЬСЯ** *сов.*— 1. атылмый калу; 2. *перен. разг.* сүзендә тукталып калу, тотлыгып калу (сөйләгәндә); 3. *простореч.* көймәсе комга утыру, уңышсызлыкка очрау; *осеклись они на этом деле* — бу эштә аларның көймәләре комга утырды.

**ОСИВЕ'ТЬ** *сов. разг. фам.*— чәч агару, чал керү.

**ОСИ'ЛИВАТЬ** *несов.*— к. осилить.

**ОСИ'ЛИТЬ** *сов. разг.*— 1. җиңү, өстен чыгу, җиңеп чыгу; *осилить неприятеля* — дошманны җиңү; 2. *разг.* җиңеп чыгу, ерып чыгу; *осилить геометрию* — геометрияне ерып чыгу; 3. *разг.* көчкә ашап бетерү, көчкә эчеп бетерү; *еле осилил кусок пирога* — бер кисәк бәлешне көчкә ашап бетердем.

**ОСИ'НА** *ж.* — усак агачы.

**ОСИ'ННИК** *м.*— 1. усак урманы, усаклык; 2. *обл.* усак утыны; *топить осинником* — усак утыны ягу.

**ОСИ'НОВЫЙ** — усак...-ы; *осиновый лист* — усак яфрагы. ◇ **Дрожит, как осиновый лист** — калтырап тора, дерелдәп тора.

**ОСИ'НЫЙ** — шөпшә...-ы; *осиный мед* — шөпшә балы. ◇ **Осиное гнездо** — 1. шөпшә оясы; 2. *перен. пренебр.* козгыннар оясы (социаль яктан зарарлы кешеләр төркеме яки аларның торагы).

**ОСИ'ПЛЫЙ** *разг.*— карлыккан; *осиплый голос* — карлыккан тавыш.

**ОСИ'ПНУТЬ** *сов. разг.*— тавыш карлыгу; *пой, поколе не осипнешь* — тавышың карлыкканчы җырлап кал.

**ОСИРОТЕ'ЛЫЙ** — 1. ятим, ятим калган; *осиротелые дети* — ятим калган балалар; 2. *перен. книж.* иясез калган, буш; *осиротелая комната* — иясез калган бүлмә.

**ОСИРОТЕ'ТЬ** *сов.*— 1. ятим калу; 2. буш калу, яме китү, яме бетү; *дом осиротел без хозяина* — хуҗасыз өйнең яме китте.

**ОСИРОТИ'ТЬ** *сов.*— ятим калдыру.

**ОСИЯ'ТЬ** *сов. книж. устар.*— яктырту; *первые лучи солнца осияли вершины гор* — кояшның беренче нурлары тау башларын яктыртты.

**ОСКА'БЛИВАТЬ** *несов.*— к. оскоблить.

**ОСКА'БЛИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— кырып төшерелү, кырып алыну, кырып чыгылу.

**ОСКА'Л** *м. мн.* нет — 1. (*действие*) к. оскалить; 2. (*приоткрытый рот с виднеющимися зубами*) ыржайган авыз.

**ОСКА'ЛИВАТЬ** *несов.*— к. оскалить.

**ОСКА'ЛИВАТЬСЯ** *несов.*— к. оскалиться.

**ОСКА'ЛИНА** *ж. спец.*— кабыгы купкан урын, сыдырылган урын; *оскалина на дереве* — агачның кабыгы купкан урыны.

**ОСКА'ЛИТЬ** *сов.*— ыржайту; *оскалить зубы* — тешләрне ыржайту.

**ОСКА'ЛИТЬСЯ** *сов.*— тешләрне ыржайту; *что ты оскалился?* — нәрсә син тешләреңне ыржайттың?

**ОСКАНДА'ЛИТЬ** *сов.*— хур итү, оятка калдыру, көлкегә калдыру.

**ОСКАНДА'ЛИТЬСЯ** *сов.* — хур булу, оятка калу, көлкегә калу.

**ОСКВЕРНИ'ТЕЛЬ** *м.*— пычратучы, шакшылаучы, шапшаклаучы.

**ОСКВЕРНИ'ТЬ** *сов.* — 1. *рел.* (*сделать нечистым*) пычрату, шакшыландыру, нәҗесләндерү; 2. *ритор.* (*запятнать, опозорить*) хур итү, пычрату, кара ягу, тап төшерү.

**ОСКВЕРНИ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. *рел.* пычрану, шакшылану, нәҗесләнү; 2. *ритор.* йөзгә кара ягылу, яман аты сатылу, хур булу, түбәнчелеккә төшү.

**ОСКВЕРНЯ'ТЬ** *несов.*— к. осквернить.

**ОСКВЕРНЯ'ТЬСЯ** *несов. книж.*— 1. к. оскверниться; 2. *страд.* пычратылу; хур ителү, түбәнлеккә төшерелү, йөзенә кара ягылу.

**ОСКЛА'БИТЬ** *сов.*— авыз еру (көлгәндә).

**ОСКЛА'БИТЬСЯ** *сов.*— тешләрен ыржайтып көлү, тешләрен ыржайтып елмаю.

**ОСКЛИЗА'ТЬСЯ** *несов. обл.*— к. осклизнуться.

**ОСКЛИ'ЗНУТЬ** *сов. простореч.*— к. ослизнуть.

**ОСКЛИЗНУ'ТЬСЯ** *сов. обл.*— таю, таеп китү.

**ОСКОБЛИ'ТЬ** *сов.*— кырып төшерү, кырып алу, кырып чыгу (өстеннән, тирә-ягыннан).

**ОСКО'ЛОК** *м.*— 1. осколок, китек, ватык, кыйпылчык; *осколок снаряда* — снаряд кыйпылчыгы; *осколок зеркала* — көзге ватыгы; 2. *перен.* калдык; *осколок старины* — борынгылык калдыгы.

**ОСКО'ЛОЧНЫЙ** *спец.*— 1. осколок...-ы; *осколочная рана* — осколок ярасы; 2. осколоклы; *осколочные бомбы* — осколоклы бомбалар.

**ОСКО'МА** *ж. мн.* нет, *простореч.*— к. оскомина.

**ОСКО'МИНА** *ж. мн.* нет, *разг.*: **набить оскомину** — 1. теш камашу; 2. *перен.*

туйдырып бетерү, йөдәтеп бетерү, теңкәгә тиеп бетү.

**ОСКО'МИСТЫЙ** *разг.* — теш камаштыргыч, теш камаштыра торган; *оскомистые яблоки* — теш камаштыра торган алмалар.
**ОСКОПИ'ТЬ** *сов.* — печү.
**ОСКОПЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. оскопить.
**ОСКОПЛЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — печелү.
**ОСКОРБИ'ТЕЛЬ** *м. книж.* — хурлаучы, йөзгә кара ягучы, мәсхәрә итүче.
**ОСКОРБИ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — хурлыклылык; *оскорбительность слов* — сүзләрнең хурлыклылыгы.

**ОСКОРБИ'ТЕЛЬНЫЙ** — хурлыклы, намуска тия торган; *оскорбительный упрёк* — намуска тия торган шелтә.
**ОСКОРБИ'ТЬ** *сов.* — хурлау, мыскыл итү, намуска тию. ◇ **Оскорбить действием** *офиц.* — кыйнау, сугу.
**ОСКОРБИ'ТЬСЯ** — хурлану, гарьләнү.
**ОСКОРБЛЕ'НИЕ** *ср.* — мыскыл итү, мыскыл ителү.
**ОСКОРБЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. оскорбить.
**ОСКОРБЛЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. оскорбиться; 2. *страд.* мыскыл ителү.
**ОСКОТИ'НИТЬСЯ** *сов. разг. презрит.* — хайванлану, кешелек төсен югалту.
**ОСКРЁБКИ** *м.* — касмак, кырынты.
**ОСКРЁБЫВАТЬ** *несов. простореч.* — к. оскрести.
**ОСКРЁБЫШ** *м. обл.* — кырынтык.
**ОСКРЕСТИ'** *сов. простореч.* — кырып төшерү, кырып алу, кырып чыгу; *оскрести ножом кухонный стол* — кухня өстәлен пычак белән кырып чыгу.
**ОСКУДЕВА'ТЬ** *несов. книж.* — ярлылана бару, фәкыйрьләнә бару.
**ОСКУДЕ'ТЬ** *сов. книж.* — ярлылану, фәкыйрьләнү.
**ОСЛАБЕВА'ТЬ** *несов.* — көчсезләнә бару, хәлсезләнә бару, көчсезләнә төшү, хәлсезләнә төшү, йомшара төшү.
**ОСЛАБЕ'ЛЫЙ** *разг.* — көчсезләнгән, хәлсезләнгән.
**ОСЛАБЕ'ТЬ** *сов.* — көчсезләнү, хәлсезләнү.
**ОСЛАБИ'ТЕЛЬ** *м. фот.* — ослабитель, йомшарткыч эремә (фотографиядә негативлардан көмешнең артык өлешен алып ташлау өчен кулланыла).
**ОСЛА'БИТЬ** *сов.* — 1. көчсезләндерү, хәлсезләндерү; *болезнь ослабила его* — авыру аны хәлсезләндергән; 2. бушайту, бушайта төшү; *ослабить пояс* — билбауны бушайту; 3. киметү, җиңеләйтү, йомшарту; *ослабить наказание* — җәзаны җиңеләйтү.
**ОСЛАБЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. ослабить.
**ОСЛАБЛЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — көчсезләндерелү, хәлсезләндерелү; кимetелү, җиңеләйтелү, йомшартылу.
**ОСЛА'БНУТЬ** *сов. разг.* — 1. к. ослабеть; 2. (*стать менее натянутым*) бушый төшү.
**ОСЛА'ВИТЬ** *сов. разг.* — исемен чыгару, хәбәр тарату; яман атын сату, яман атын чыгару, гайбәт тарату; *ославили его пьяницей* — исерек баш дип, аның яман атын чыгардылар.
**ОСЛА'ВИТЬСЯ** *сов. разг.* — исеме чыгу, яман аты сатылу.
**ОСЛАВЛЯ'ТЬ** *несов. разг.* — к. ославить.
**ОСЛАВЛЯ'ТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. к. ославиться; 2. *страд.* исеме чыгарылу, гайбәт таратылу, яман аты сатылу.
**ОСЛЕ'ДИНА** *ж. спец.* — агач башы, агач кәүсәсенең очы; *доски из осле́дины* — агач башыннан ярылган такталар.
**ОСЛЁНОК** *м.* (*мн.* ослята) — ишәк баласы.
**ОСЛЕПИ'ТЕЛЬНЫЙ** — 1. күз чагылдыргыч, күз чагылдырырлык, күз явын алырлык; *рубашка ослепительной белизны* — күз чагылдырырлык ак күлмәк; 2. *перен.* хәйран калырлык, шаккатарлык, искиткеч; *женщина ослепительной красоты* — искиткеч матур хатын.
**ОСЛЕПИ'ТЬ** *сов.* — 1. (*лишить зрения*) сукырайту; 2. күз чагылдыру; *свет ослепил меня* — яктылык күземне чагылдырды; 3. *перен.* (*ввести в заблуждение*) ялгыштыру, юлдан яздыру; 4. *перен.* шаккатыру, хәйран калдыру, искитәрү; *она ослепила его своей красотой* — ул аны үз нең матурлыгы белән хәйран калдырган.
**ОСЛЕПИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. ялгышу, юлдан язу; 2. шаккату, ис китү, хәйран калу.
**ОСЛЕПЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. ослепить.
**ОСЛЕПЛЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. ослепиться; 2. *страд.* сукырайтылу; 3. *страд. перен.* ялгыштырылу, юлдан яздырылу.
**ОСЛЕ'ПНУТЬ** *сов.* — сукыраю.
**ОСЛИ'ЗЛЫЙ** — тайгак, лайлалы.
**ОСЛИ'ЗНУТЬ** *сов. разг.* — тайгаклану, лайлалану.
**О'СЛИК** *м.* — кечкенә ишәк.
**ОСЛИ'ННИК** *м. бот.* — ишәк колагы (үсемлек).
**ОСЛИ'НЫЙ** — ишәк...-ы; *ослиные уши* — ишәк колаклары.
**ОСЛИ'ТЬ** *несов. разг. фам. шутл.* — тупас сүз әйтү, тупас рәвештә төрттереп кую (сүз әйтеп).
**ОСЛИ'ЦА** *ж.*, **ОСЛИ'ХА** *ж. обл.* — ана ишәк. ◇ **Валаамова ослица заговорила** *книж. ирон.* — Валаам ишәге дә телгә килде (каршы сүз әйтми торган юаш кеше каршы эндәшкәндә әйтелә).
**ОСЛОЖНЕ'НИЕ** *ср.* — 1. *только ед.* (*действие*) к. осложнить, осложниться; 2. кыенлык, читенлек, авырлык, тоткарлык, комачаулык; *дипломатические осложнения* — дипломатик кыенлыклар. ◇ **Грипп с осложнением на уши** — грипптан колаклар авырта башлау.
**ОСЛОЖНИ'ТЬ** *сов.* — катлауландыру, читенләштерү, кыенлаштыру.
**ОСЛОЖНИ'ТЬСЯ** *сов.* — катлаулану, читенләшү, кыенлашу; *дело осложнилось* — эш кыенлашты.
**ОСЛОЖНЯ'ТЬ** *несов.* — к. осложнить.
**ОСЛОЖНЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. осложниться; 2. *страд.* катлауландырылу, кыенлаштырылу, читенләштерелү.

**ОСЛО'П** *м. обл.* — кусәк, колга.
**ОСЛУ'ШАТЬСЯ** *сов.* — сүз тыңламау, буйсынмау, карышу, кушканны эшләмәү, киреләнү, тискәреләнү.
**ОСЛУ'ШИВАТЬСЯ** *несов.* — к. ослушаться.
**ОСЛУ'ШНИК** *м.*, **ОСЛУ'ШНИЦА** *ж. устар.* — сүз тыңламаучан кеше, тискәре кеше, үзсүзле кеше.
**ОСЛЫ'ШАТЬСЯ** *сов.* — ишетеп җиткермәү, ялгыш ишетү.
**ОСЛЯ'К** *м. зоол.* — 1. (*дикий осёл*) кыр ишәге, кыргый ишәк; 2. к. мул.
**ОСЛЯ'ТИНА** *ж.* — 1. ишәк ите; 2. *простореч. бран.* ишәк (тискәре кешегә карата әйтелә).
**ОСЛЯ'ТНИК** *м. устар.* — ишәк көтүчесе.
**ОСМА'ЛИВАТЬ** *несов.* — сумалалау (тирәли сумалалап чыгу).
**ОСМА'ЛИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — сумалалану, тирәли сумалалап чыгылу.
**ОСМА'НЦЫ** *мн. устар.* — госманлылар, госманлы төрекләр.
**ОСМА'НЫ** *мн.* — к. османцы.
**ОСМА'ТРИВАТЬ** *несов.* — к. осмотреть.
**ОСМА'ТРИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. осмотреться; 2 *страд.* карап чыгылу, каралу.
**ОСМЕ'ИВАТЬ** *несов.* — к. осмеять.
**ОСМЕ'ИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — көлкегә калдырылу.
**ОСМЕЛЕ'ТЬ** *сов.* — кыюлану, кыюланып китү.
**ОСМЕ'ЛИВАТЬСЯ** *несов.* — к. осмелиться.
**ОСМЕ'ЛИТЬСЯ** *сов.* — кыюлану, батырлыгы җитү, батырчылык итү, кулы бару. ◇ **Осмелюсь доложить** *дореволь.* — рөхсәт итегез әйтергә.
**ОСМЕЯ'ТЬ** *сов.* — көлкегә калдыру.
**О'СМИЙ** *м. хим.* — осмий (химик элемент, ак алтын группасыннан булган металл).
**ОСМО'Л** *м. спец.* — 1. нарат агачының төбе; 2. *только ед.* к. осмолка.
**ОСМОЛИ'ТЬ** *сов.* — сумалалау, сумалалап чыгу.
**ОСМО'ЛКА** *ж. мн.* нет, *спец.* — к. осмолить.
**ОСМО'ЛЬЩИК** *м. спец.* — сумалалаучы (эшче).
**ОСМО'ТР** *м. мн.* нет — к. осмотреть.
**ОСМОТРЕ'ТЬ** *сов.* — 1. (*окинуть взглядом*) күз йөртеп чыгу, күздән кичерү; 2. карап чыгу; *осмотреть музей* — музейны карап чыгу; 3. тикшереп чыгу, тикшереп карап чыгу; *осмотреть багаж* — багажны тикшереп чыгу; 4. карау; *доктор осмотрел больных* — доктор авыруларны карады.
**ОСМОТРЕ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. (*поглядеть вокруг себя*) тирә-якка карану; 2. күнегү, ияләшү, тирә-як белән танышу; *я осмотрелся на новом месте* — мин яңа урынга ияләштем.
**ОСМОТРИ'ТЕЛЬНО** *нареч.* — алдын-артын уйлап, саклык белән, бик сак; *поступать осмотрительно* — алдын-артын уйлап эш итү.
**ОСМОТРИ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет — зур саклык; *действовать с осмотрительностью* — зур саклык белән эш итү.
**ОСМОТРИ'ТЕЛЬНЫЙ** — бик сак, алдын-артын уйлап эшләүчән, уяу; *осмотрительный человек* — бик сак кеше.
**ОСМО'ТРЩИК** *м.* — тикшерүче, тикшереп карап торучы; *осмотрщик вагонов* — вагоннар тикшерүче.
**ОСМЫ'СЛЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — акыл белән эшләнгәнлек, уйлап эшләнгәнлек, уйланганлык, мәгънәлелек.
**ОСМЫ'СЛЕННЫЙ** *книж.* — 1. аңлашылган; 2. мәгънәле, аңлы, акыл белән эшләнгән; *осмысленный взгляд* — аңлы караш.
**ОСМЫ'СЛИВАТЬ** *несов. книж.* — к. осмыслить.
**ОСМЫ'СЛИТЬ** *сов. книж.* — аңлау, төшенү; *правильно осмыслить исторические явления* — тарихи күренешләрне дөрес аңлау.
**ОСМЫСЛЯ'ТЬ** *несов. книж* — к. осмыслить.
**ОСНАСТИ'ТЬ** *сов.* — 1. җиһазландыру; *оснастить корабль* — корабльне җиһазландыру; 2. (*снабдить вооружением*) кораллландыру.
**ОСНА'СТКА** *ж. мн.* нет — 1. (*действие*) к. оснастить; 2. җиһаз (корабль палубасындагы җиһазлар); *корабль в новой оснастке* — палубасына яңа җиһазлар куелган корабль.
**ОСНАЩА'ТЬ, ОСНА'ЩИВАТЬ** *несов.* — к. оснастить.
**ОСНАЩА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — җиһазландырылу; кораллландырылу.
**ОСНА'ЩИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — к. оснащаться.
**ОСНЕЖИ'ТЬ** *сов. книж.* — кар белән каплау; *зима оснежила поля* — кыш басуларны кар белән каплады.
**ОСНО'ВА** *ж.* — 1. *чаще ед.* нигез, төп; *за основу принято предложение докладчика* — нигез итеп докладчының тәкъдиме алынды; 2. *только ед.* терәк, кыса; *у этого дивана дубовая основа* — бу диванның кысасы имән агачыннан ясалган; 3. *только мн.* төп нигезләр, төп принциплар; *основы химии* — химиянең төп нигезләре; 4. *тех.* (*продольные нити в ткацком деле*) буй җеп, буйлык (туку эшендә буй җеп); 5. *лингв.* нигез (сүзнең тамырдан һәм ясагыч кушымчалардан тора торган өлеше).
**ОСНОВА'НИЕ** *ср.* — 1. *чаще ед.* салыну, төзелү; *год основания университета* — университет төзелгән ел; 2. (*принцип*) төп, нигез; 3. сәбәп, дәлил; *серьёзные основания* — җитди дәлилләр; 4. нигез; *дом на каменном основании* — таш нигезле өй. ◇ **До основания** — бөтенләй, бөтенләйгә; *дом сгорел до основания* — өй бөтенләй янып беткән.
**ОСНОВА'ТЕЛЬ** *м.* — нигезләүче, коручы, салучы, ни ез салучы; *основателем Петербурга был Петр I* — Петербург шәһәрен салучы Пётр I булды.
**ОСНОВА'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет — төплелек, нигезлелек, дәлилле лек; *сделано с большой основательностью* — зур төп-

лелек белән эшләнгән, бик нигезле эшләнгән.

**ОСНОВА'ТЕЛЬНЫЙ** — 1. нигезле, дәлилле; *основательное требование* — нигезле таләп; 2. төпле, җитди; *основательный человек* — төпле кеше; *основательное изучение* — җитди өйрәнү; 3. нык; *основательный мост* — нык күпер; 4. *разг. шутл.* шактый зур, шактый күп, шактый авыр; *основательная туша* — шактый зур түшкә; *основательный чемодан* — шактый авыр чемодан.

**ОСНОВА'ТЬ** *сов.* — 1. салу, кору, оештыру; *основать город* — шәһәр салу; *основать больницу* — больница оештыру; 2. (*обосновать*) нигезләү, дәлил китерү.

**ОСНОВА'ТЬСЯ** *сов.* — урнашу; *он основался в новом доме* — ул яңа өйгә урнашкан.

**ОСНОВНИ'К** *м. спец. разг.* — төп хезмәткәр, штаттагы хезмәткәр.

**ОСНОВНО'Й** — 1. иң әһәмиятле, төп, иң мөһим; *основная цель* — төп максат; 2. *в знач. сущ.* төп момент, эшнең асылы, нигезе; *не надо упускать из виду основного* — төп моментны күз алдыннан ычкындырмаска кирәк. ◇ **В основном работа выполнена** — нигездә эш тәмамланган, нигездә эш беткән.

**ОСНО'ВНЫЙ** *ткац.* — буй, буйлык...-ы; *основные нити* — буйлык җепләре.

**ОСНОВОПОЛАГА'ЮЩИЙ** *книж.* — нигез сала торган, төп; *основополагающий принцип естественных наук* — табигать фәннәренең төп принцибы.

**ОСНОВОПОЛО'ЖНИК** *м. книж.* — нигез салучы, нигезләүче; *основоположники марксизма* — марксизмның нигезен салучылар.

**ОСНОВОПОЛО'ЖНЫЙ** *книж.* — төп, мөһим, нигез сала торган.

**ОСНО'ВЩИК** *м. спец.* — основщик (тукыма станогында буйлыкны төзәтүче).

**ОСНО'ВЫВАТЬ** *несов.* — к. основать.

**ОСНО'ВЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. основаться; 2. *страд.* нигезләнү, таяну, дәлилләнү; *обвинение основывается на проверенных фактах* — гаепләү тикшерелгән фактлар белән нигезләнә.

**ОСО'БА** *ж.* — 1. *устар. ирон.* (*важный человек*) тәкәббер кеше, эре кеше, түрә; 2. бер кеше, кемдер берәү; *неизвестная особа* — билгесез бер кеше; 3. *ирон. шутл.* гәүдә; *тучная особа купца* — купецның симез гәүдәсе.

**ОСО'БЕННО** *нареч.* — 1. аеруча, бик үк; *особенно красивый* — аеруча матур; *было не особенно весело* — бик үк күңелле булмады; 2. *разг.* (*главным образом*) бигрәк тә; 3. *устар.* (*отдельно, особо*) аерым.

**ОСО'БЕННОСТЬ** *ж. книж.* — үзенчәлек, башкалык, аерымлылык. ◇ **В особенности** — бигрәк тә, аеруча.

**ОСО'БЕННЫЙ** — 1. үзенә бер төрле, аерым, үзенә башка; *обед подавался на особенном сервизе* — аш үзенә бер төрле аерым сервизда китерелә иде; 2. артык зур, зур; *он лёг рано, без особенного желания спать* — йокларга артык зур теләге булмаса да, ул иртә ятты; 3. *устар.* үзенә башка, аерым; *он жил в особенной комнате* — ул аерым бер бүлмәдә тора иде.

**ОСО'БИТЬСЯ** *несов. устар.* — читтә тору, аралашмау; *он всё от людей особится* — ул һәрвакыт кешеләрдән читтә тора; ул бервакытта да кешеләр белән аралашмый.

**ОСО'БИЦА** *ж. просторе*ч. *устар.*: **в особицу** — үзе генә, бер үзе, башкалардан аерым; *действовать в особицу* — аерым эш итү.

**ОСОБЛИ'ВЫЙ** *устар.* — к. особенный.

**ОСО'БНЫЙ** *устар. книж.* — аерым, үзенә башка, ялгыз.

**ОСОБНЯ'К** *м.* — аерым йорт (бай хуҗаның аерым йорты).

**ОСОБНЯКО'М** *нареч.* — аерым, ялгыз, бер үзе; *дом стоит особняком за чертой города* — йорт шәһәр читендә бер үзе тора.

**ОСО'БО** *нареч.* — 1. аерым, үзенә башка; *положи эту книгу особо* — бу китапны үзенә башка бер җиргә алып куй; 2. *устар.* бигрәк тә, аеруча; *особо вкусное блюдо* — бигрәк тә тәмле аш; *это мне особо нравится* — бу миңа аеруча ошый.

**ОСО'БЫЙ** — 1. к. особенный 1; 2. аерым, махсус; *особый указ* — махсус указ; *эту мысль надо изложить в особом параграфе* — бу фикерне аерым бер параграф итеп бирергә кирәк; 3. үзенә бер төрле, аерым; *одеколон с совершенно особым запахом* — бу одеколоннан үзенә бер төрле ис килеп тора. ◇ **Особое мнение** *офиц.* — аерым бер фикер (күпчелекнең фикере белән килешмәү).

**О'СОБЬ** *ж. науч.* — зат, шәхес, индивид.

**ОСО'БЬ** *устар.*: **особь статья** — ул башка нәрсә, бөтенләй башка нәрсә; *дело о лесе — особь статья* — урман мәсьәләсе — ул бөтенләй башка нәрсә.

**ОСОВЕ'ЛЫЙ** *разг. фам.* — сәлперәйгән, мәлҗерәгән; *осовелый вид* — мәлҗерәгән кыяфәт. ◇ **Осовелые глаза** — тонган күзләр.

**ОСОВЕ'ТЬ** *сов. разг. фам.* — сәлперәю, мәлҗерәү; күзләре тону.

**ОСОЕ'Д** *м. зоол.* — шөпшә кошы, шөпшәашар (лачынсыманнар семьясыннан).

**ОСОЗНАВА'ТЬ** *несов.* — к. осознать.

**ОСОЗНАВА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — аңлану, аңлап үзләштерелү.

**ОСОЗНА'ТЬ** *сов.* — аңлау, төшенү, аңлап үзләштерү, төшенеп җитү; *осознать классовые интересы* — сыйнфый интересларны аңлау.

**ОСО'КА** *ж. мн.* нет — кыяк, кыяк үләне, күрән.

**ОСОКО'РНИК** *м.* — кара тирәклек, кара тирәк урманы.

**ОСОКО'РЬ** *м.* — кара тирәк, кара тополь.

**ОСОЛОВЕ'ЛЫЙ** *разг.* — к. осовелый.

**ОСОЛОВЕ'ТЬ** *сов.* — мәлҗерәү, йокымсырау, изрәү.

**ОСОЛОДЕ'ТЬ** *сов. обл.* — салатлану, салатланып бетү.

**ОСОПЛИ'ВЕТЬ** *сов. простореч. вульг.*— маңкалану, маңкалау; *мальчишка осопливел* — малай маңкалаган.

**ОСО'Т** *м. бот.* — билчән (чүп үлән).

**ОСО'ТОВЫЙ** *бот.* — билчән...-ы; *осотовый корень* — билчән тамыры.

**О'СПА** *ж. мн.* нет — 1. чәчәк (авыру); 2. шадра; *лицо в оспе* — шадра бит. ◇ **Ветряная оспа** — җил чәчәге, су чәчәге. **Привить оспу** — чәчәк салдыру, чәчәк салу.

**ОСПА'РИВАТЬ** *несов.* — 1. килешмәү, каршы килү, бәхәсләшү; *не оспаривай глупца* — ахмак кеше белән бәхәсләшмә; 2. даулау, алырга тырышу; *оспаривать звание чемпиона* — чемпион исемен алырга тырышу.

**ОСПА'РИВАТЬСЯ** *несов. страд. книж.*— дәгъва ителү.

**О'СПЕННЫЙ** — 1. чәчәк...-ы; *оспенные бациллы* — чәчәк бациллалары; 2. шадра; *оспенное лицо* — шадра бит.

**О'СПИНА** *ж. разг.* — чәчәк шадрасы.

**ОСПОПРИВИВА'НИЕ** *ср. книж.* — чәчәк салу, чәчәк салдыру.

**ОСПОПРИВИВА'ТЕЛЬ** *м.*, **ОСПОПРИВИВА'ТЕЛЬНИЦА** *ж. спец.* — чәчәк салучы.

**ОСПОПРИВИВА'ТЕЛЬНЫЙ** *мед.*— чәчәк салу...-ы; чәчәк салдыру...-ы; *оспопрививательные материалы* — чәчәк салу материаллары; *оспопрививательный пункт* — чәчәк салдыру пункты.

**ОСПО'РИВАТЬ** *несов* — к. оспаривать.

**ОСПОРИ'МЫЙ** *книж.* — бәхәсле, шикле, шөбһәле, ышанычсыз; *оспоримые доводы*— бәхәсле дәлилләр.

**ОСПО'РИТЬ** *сов.* — к. оспаривать.

**ОСРАМИ'ТЬ** *сов.*— оятка калдыру, оятлы итү, хур итү.

**ОСРАМИ'ТЬСЯ** *сов.* — оятка калу, оятлы булу, хур булу; *осрамился перед новым человеком* — яңа кеше алдында оятка калдым.

**ОСТ** I *м. тех.* (общесоюзный стандарт)— ост (союз күләмендә кабул ителгән гомуми стандарт).

**ОСТ** II *м. мор.*— көнчыгыш.

**ОСТАВА'ТЬСЯ** *несов.* — к. остаться. ◇ **Счастливо оставаться** — исән булыгыз, сау булыгыз, хушыгыз.

**ОСТА'ВИТЬ** *сов.* — 1. калдыру; *оставил записку* — язу калдырды; 2. онытып калдыру; *оставить калоши в поезде* — поездда калошны онытып калдыру; 3. китү; *оставь нас* — кит безнең яннан; 4. ташлап китү, калдырып китү; *на кого ты меня оставил* — кемгә ташлап киттең син мине; 5. *книж.* ташлау, хезмәттән чыгу, өзү, оныту; *давно ли ты службу оставил?* — кайчан хезмәттән чыктың син? *оставь надежду навсегда* — мәңгегә өметенне өз; 6. бәйләнмәү, борчымау; *оставьте меня!* — борчымагыз мине! калдырыгыз мине! 7. *устар.* гафу итү, кичерү; *оставь мне вину мою* — кичер минем гаебемне; 8. *повел. накл.* (*при отрицании и опровержении*) ташла, ташлагыз әле; *оставьте этот спор* — ташлагыз әле шул бәхәсне. ◇ **Оставить мир** *устар.* — үлү, вафат булу, дөнья кую. **Оставить за собой** — калдыру; *оставить за собой место* — үзенә урын калдыру. **Оставить позади** — артта калдыру, узып китү. **Оставить с носом** — буш калдыру, коры калдыру. **Оставить в дураках** — төпсез чанага утырту, кәкре каенга терәтү. **Камня на камне не оставить** — к. камень.

**ОСТАВЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. оставить. ◇ **Оставляет желать многого или лучшего** — яхшырак булуны таләп итә, шәптән түгел.

**ОСТАВЛЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — калдырылу.

**ОСТАЛЬНО'Й** — 1. калганы, калганнары, бүтәне, башкасы; *возьми сколько надо, а остальное убери* — кирәк булган кадәрен ал да, калганнарын җыеп куй; 2. *в знач. сущ.* башкалар; *нужно спросить у остальных* — башкалардан сорарга кирәк.

**ОСТАНА'ВЛИВАТЬ** *несов.* — к. остановить.

**ОСТАНА'ВЛИВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. остановиться; 2. *страд.* туктатылу.

**ОСТА'НКИ** *ед.* нет, *ритор.* — 1. үлек, мәет; 2. *устар. поэт.* калдыклар; *останки разорённой сени* (Пушкин) — бөлгенлеккә төшерелгән торак калдыклары.

**ОСТАНОВИ'ТЬ** *сов.* — 1. туктату; *нужно было остановить лошадь* — атны туктатырга кирәк иде; 2. (*сдержать, запретить*) тыю, туктату; 3. *перен. книж.* төшү, төшерү, ташлау, юнәлдерү; *остановить на ком-н. свои подозрения* — берәр кешегә шик төшерү. ◇ **Остановить внимание** — игътибар бирү. **Остановить взгляд** — күз төшерү.

**ОСТАНОВИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. туктау, тукталу; *войска остановились близ Полтавы* — гаскәрләр Полтава шәһәре янында туктадылар; *работа временно остановилась* — эш вакытлыча тукталды; 2. төшү, туктау; *я остановился в гостинице* — мин гостиницага төштем; 3. тыелу, туктау; *начнёт рассказывать и остановиться не может* — сөйли башласа, туктый да алмый; 4. тукталу; *остановимся на следующих фактах* — түбәндәге фактларга тукталыйк. ◇ **Он ни перед чем не остановится** — ул бернәрсә белән дә хисаплашмас.

**ОСТАНО'ВКА** *ж.* — 1. (*действие*) к. остановить, остановиться; 2. (*временный перерыв*) вакытлыча туктап тору; 3. *разг.* остановка, тукталыш; *выйдем на следующей остановке* — киләсе остановкада төшәрбез; *надо проехать еще одну остановку* — тагын бер остановка барасы бар. ◇ **Остановка за чем** *разг.* — эш нәрсәдә тора. **Без остановки**— туктаусыз.

**ОСТАНО'ВОЧНЫЙ** спец. — туктау...-ы, тукталу...-ы; *остановочный пункт* — тукталу пункты.

**ОСТА'ТОК** *м.* — 1. калдык, калган өлеш; *остатки обеда* — обед калдыклары; *остаток суммы выдан на руки* — сумманың калган өлеше кулларына бирелгән;

2. *только ед.* калган өлеш; *остаток жизни* — гомернең калган өлеше; *остаток дня* — көннең калган өлеше; 3. *мат.* калдык; *при делении семи на три в остатке получается единица* — җидене өчкә бүлсәң, калдык бер була.

**ОСТА'ТОЧНЫЙ** *спец.* — калдык...; *остаточные товары* — калдык товарлар.

**ОСТА'ТЬСЯ** *сов.* — калу; *он остался дома* — ул өйдә калды; *остаться при своём мнении* — үз фикереңдә калу. ◇ **Остаться при желании** *устар.* — теләгенә ирешә алмау. **Остаться на бумаге** — кәгазьдә калу, эшкә ашмау. **Остаться в живых** — үлми калу.

**ОСТАШИ'** *ед.* нет, *обл.* — күн итек (кунычы буямаган, тупас күннән тегелгән итек).

**ОСТЕБЕЛИ'ТЬСЯ** *сов. бот.* — сабаклану, сабакка утыру, тупсага утыру; *озимь уже остебелилась* — уҗым сабакка утырган инде, тупсага утырган инде.

**ОСТЕКЛЕНЕ'ТЬ** *сов.* — тону; *глаза остекленели* — күзләре тонган.

**ОСТЕКЛЕ'ТЬ** *сов.* — пыяла кебек ялтыравык төс алу; пыяла кебек тигез булып калу, күзге кебек ялтырау.

**ОСТЕКЛИ'ТЬ** *сов.* — пыяла кую, пыялалау; *остеклить рамы* — тәрәзә рамнарына пыяла кую.

**ОСТЕКЛЯ'НИТЬСЯ** *сов.* — к. остеклеть.

**ОСТЕКЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. остеклить.

**ОСТЕКЛЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — пыяла куелу, пыялалану.

**ОСТЕОЛОГИ'ЧЕСКИЙ** — остеологик, остеология...-ы; *остеологическое учение* — остеологик тәгълимат; *кабинет остеологии* — остеология кабинеты.

**ОСТЕОЛО'ГИЯ** *ж.* — остеология (анатомиянең скелетны һәм сөякләрнең төзелешен өйрәнү бүлеге).

**ОСТЕОТОМИ'Я** *ж. мед.* — остеотомия (сөякнең бер өлешен кисеп ташлау).

**ОСТЕПЕНИ'ТЬ** *сов.* — басынкыландыру, тынычландыру, акылга утырту.

**ОСТЕПЕНИ'ТЬСЯ** *сов.* — басынкылану, тынычлану, акылга утыру; *женился, остепенился* — өйләнгәч акылга утырды.

**ОСТЕПЕНЯ'ТЬ** *несов.* — к. остепенить.

**ОСТЕПЕНЯ'ТЬСЯ** *несов.* — к. остепениться.

**ОСТЕРВЕНЕ'ЛЫЙ** — котырган, шашкан; *остервенелый взгляд* — шашкан караш.

**ОСТЕРВЕНЕ'ТЬ** *сов. разг.* — котыру, шашу, бик нык ачу килү.

**ОСТЕРВЕНИ'ТЬ** *сов.* — котырындыру, шаштыру, бик нык ачуландыру, шашындыру.

**ОСТЕРВЕНИ'ТЬСЯ** *сов.* — котырыну, шашыну, бик нык ачу килү.

**ОСТЕРЕГА'ТЬ** *несов.* — к. остеречь.

**ОСТЕРЕГА'ТЬСЯ** *несов.* — саклану, сак булу; *остерегайтесь собак* — этләрдән сакланыгыз.

**ОСТЕРЕ'ЧЬ** *сов.* — сак булырга кушу, сакланырга кушу; алдан искәртү.

**ОСТЕРЕ'ЧЬСЯ** *сов.* — к. остерегаться.

**ОСТЕРИ'Я** *ж.* — трактир, ашханә (Италиядә түбән разрядлы ресторан).

**ОСТИ'СТОСТЬ** *ж. мн.* нет, *спец.* — кылчыклылык; *остистость пшеницы* — бодайның кылчыклылыгы.

**ОСТИ'СТЫЙ** *спец.* — кылчыклы; *остистая рожь* — кылчыклы арыш.

**О'СТОВ** *м.* — 1. каркас (берәр корылманың скелеты); *остов судна* — судноның каркасы; 2. *(костяк, скелет)* скелет; 3. *перен. книж.* нигез, төп фикер; *остов сочинения* — әсәрнең нигезе, әсәрнең төп фикере.

**ОСТОЛБЕНЕ'ЛЫЙ** *разг.* — катып калган; *он стоял, как остолбенелый* — ул катып калган кебек басып тора иде.

**ОСТОЛБЕНЕ'ТЬ** *сов. разг.* — катып калу.

**ОСТОЛО'П** *м. разг. фам. бран.* — ангыра, мәнсез, ахмак, тинтәк, күзле букән.

**ОСТОРО'ЖНИЧАТЬ** *несов. разг. неодобр.* — артык саклык күрсәтү, артык сак булу.

**ОСТОРО'ЖНОСТЬ** *ж. мн.* нет — саклык, сак булу, сак булучанлык.

**ОСТОРО'ЖНЫЙ** — сак, уяу, саклanучан; *осторожный человек* — сак кеше.

**ОСТОЧЕРТЕ'ТЬ** *сов. разг. фам.* — теңкәне корыту, теңкәгә тию, биздерү, туйдыру.

**ОСТРА'ГИВАТЬ** *несов.* — ышкылап чыгу, тирәли ышкылап чыгу.

**ОСТРА'ГИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — ышкылап чыгылу, тирәли ышкылап чыгылу.

**ОСТРАКИ'ЗМ** *м. книж. ритор.* — остракизм, илдән сөрү, сөргенгә җибәрү (борынгы грекларда).

**ОСТРА'СТКА** *ж. разг.* — куркыту, курку салу; *наказать для острастки* — куркыту өчен җәза бирү.

**ОСТРЕЁ** *ср.* — к. остриё.

**ОСТРЕ'Ц** *м. бот.* — кыяк үләне, сарут.

**ОСТРИГА'ТЬ** *несов.* — к. остричь.

**ОСТРИГА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. остричься; 2. *страд.* кыркылу, киселү, алыну.

**ОСТРИЁ** *ср.* — 1. оч; *остриё иголки* — инә очы; 2. йөз (кисү коралының үткен ягы); *остриё ножа* — пычак йөзе; 3. *перен. книж.* иң үткен як; *остриё критики* — тәнкыйтьнең иң үткен ягы.

**ОСТРИ'ЛЬНЫЙ** *спец.* — кайрау...-ы, үткенләү...-ы; *остриильный прибор* — кайрау приборы.

**ОСТРИ'ТЬ** I *несов. книж.* — 1. (*делать острым*) үткенләү, кайрау, чарлау; 2. *перен.* сизгерләндерү, зирәкләндерү; *острить ум* — акылны зирәкләндерү. ◇ **Острить зуб или зубы** *устар.* — теш кайрау.

**ОСТРИ'ТЬ** II *несов.* — тапкыр сүз әйтү, үткен сүз әйтү; *он удачно острит* — ул үткен сүз әйтергә оста.

**ОСТРИ'ЦА** *ж. зоол.* — бабасыр (суалчан).

**ОСТРИ'ЧЬ** *сов.* — 1. кырку; алдыру, алу (йонын, чәчен); *остричь волосы* — чәчне алдыру; *остричь барана* — тәкәнең йонын кырку; 2. кисү; *остричь ногти* — тырнак кисү.

**ОСТРИ'ЧЬСЯ** *сов.* — чәч алдыру.

**О'СТРОВ** *м.* — утрау, атау.

**ОСТРОВЕ'РХИЙ** — очлы башлы; *островерхий минарет* — очлы башлы манара.

**ОСТРОВИ'НА** *ж. разг.* — бик зур утрау.

**ОСТРОВИТЯ'НИН** *м.*, **ОСТРОВИТЯ'НКА** *ж.* — утрауда яшәүче.

**ОСТРОВНО'Й** — утрау...-ы; утрауга урнашкан; *островная растительность* — утрау үсемлекләре; *островной город* — утрауга урнашкан шәһәр.

**ОСТРОВО'К** *м.* — кечкенә утрау.

**ОСТРОВСКО'Й** *разг.* — к. островной.

**ОСТРО'ВЬЕ** *ср. собир. обл.* — шеш (кибәнгә кадап куяр өчен); *заготовить островье* — шеш хәзерләп кую.

**ОСТРО'Г** *м.* — 1. *устар. (тюрьма)* төрмә, зиндан, баструк; 2. *истор. (укреплённый пункт)* крепость, ныгытма; 3. *истор. (крепостная стена)* крепость стенасы.

**ОСТРОГА'** *ж.* — острога, балык кадагыч (сәнәксыман багор, балык тоту өчен кулланыла).

**ОСТРОГА'ТЬ** *сов.* — к. обстрогать.

**ОСТРОГЛА'ЗЫЙ** *разг.* — зирәк, үткен күзле; *остроглазый мальчишка* — үткен күзле малай.

**ОСТРОГО'ВЫЙ** *спец.* — чәнчеп тота торган (балык турында); *остроговая рыба* — чәнчеп тота торган балык.

**ОСТРОГОЛО'ВЫЙ** — очлы башлы, озынча башлы; *остроголовый мальчик* — озынча башлы малай.

**ОСТРОГО'РБЫЙ** — очлы бөкреле; *острогорбый человек* — очлы бөкреле кеше.

**ОСТРОГРУ'ДКА** *ж. зоол.* — очлытүш (су коңгызының бер төре).

**ОСТРОГУ'БЦЫ** *ед.* нет — карга борын (келәшчәнең бер төре).

**ОСТРОДЕФИЦИ'ТНЫЙ** — бик дефицитлы; *остродефицитный товар* — бик дефицитлы товар.

**ОСТРО'ЖЕК** *м. истор.* — 1. (*крепостная стена*) крепость стенасы; 2. крепость.

**ОСТРО'ЖНИК** *м. устар.* — арестант, тоткын.

**ОСТРО'ЖНЫЙ** *устар.* — төрмә...-ы; *острожная одежда* — төрмә киеме.

**ОСТРОЗАРА'ЗНЫЙ** *мед.* — 1. үтә йогышлы, бик йогышлы; *острозаразная болезнь* — үтә йогышлы авыру; 2. үтә йогышлы авырулар...-ы; *острозаразный барак* — үтә йогышлы авырулар барагы.

**ОСТРОЗУ'БЦЫ** *ед.* нет — к. острогубцы.

**ОСТРОЗУ'БЫЙ** — үткен тешле; *острозубая акула* — үткен тешле акула.

**ОСТРОКЛЮ'ВЫЙ** — үткен томшыклы, очлы томшыклы; *остроклювая птица* — үткен томшыклы кош.

**ОСТРОКОНЕ'ЧНЫЙ** — үткен очлы, очлы башлы; *остроконечная палка* — очлы башлы таяк.

**ОСТРОКРЫ'ЛЫЙ** — очлы канатлы; *острокрылая птица* — очлы канатлы кош.

**ОСТРОЛИ'СТ** *м. бот.* — очлы яфрак (коньякта үсә торган мәңге яшел үсемлек).

**ОСТРОЛИ'СТЫЙ** — очлы яфраклы...; *остролистая ива* — очлы яфраклы тал.

**ОСТРОЛИ'ЦЫЙ** — озынча битле, озынча йөзле; *остролицый человек* — озынча битле кеше.

**ОСТРОНО'СИК** *м. разг. шутл. пренебр.* — очлы борын.

**ОСТРОНО'СЫЙ** — 1. очлы борынлы; *остроносый мальчишка* — очлы борынлы малай; 2. очлы башлы; *остроносые туфли* — очлы башлы туфли.

**ОСТРОПИ'ЛИВАТЬ** *несов. спец.* — бәбкә салу, атлама кую (өй яки башка нәрсә түбәсенә).

**ОСТРОПИ'ЛИТЬ** *сов. спец.* — к. остропиливать.

**ОСТРОРЫ'ЛЫЙ** *спец.* — озын борынлы; *острорылая собака* — озын борынлы эт.

**ОСТРОСЛО'В** *м. книж.* — тапкыр сүзле, үткен сүзле кеше, үткен сүз яратучы.

**ОСТРОСЛО'ВИТЬ** *несов. книж.* — тапкыр сүзләр әйтү, үткен сүзләр әйтү.

**ОСТРОТА'** *ж.* — 1. *только ед.* үткенлек; *острота ножа* — пычакның үткенлеге; *острота зрения* — күзнең үткенлеге; 2. *только ед.* ачылык, ачы; *в соусе мало остроты* — соуста ачылык аз; 3. *только ед.* кискенлек; *острота положения* — хәлнең кискенлеге; 4. (*остроумное выражение*) тапкыр сүз, үткен сүз. ◇ **Острота ума** — акылның зирәклеге. **Острота запаха** — иснең борынга бәрелеп торуы. **Дешёвые остроты** — арзан тапкырлык, тупас тапкырлык.

**ОСТРОУГО'ЛЬНИК** *м. мат.* — кысынкы почмаклык.

**ОСТРОУГО'ЛЬНЫЙ** — кысынкы почмаклы; *остроугольный треугольник* — кысынкы почмаклы өчпочмак.

**ОСТРОУ'М** *м.*, **ОСТРОУ'МЕЦ** *м. разг. устар.* — үткен фикерле кеше, үткен сүзле кеше, сүзгә тапкыр кеше.

**ОСТРОУ'МИЕ** *ср. мн.* нет — үткен фикерлелек, үткен сүзләргә тапкырлык, тапкыр сүзлелек.

**ОСТРОУ'МНИЧАТЬ** *несов. разг. неодобр.* — үткен фикерле булып күренергә тырышу, үткен фикерлелек күрсәтергә маташу.

**ОСТРОУ'МНЫЙ** — үткен фикерле, үткен сүзле, тапкыр; үткен; *эпиграммы Пушкина очень остроумны* — Пушкинның эпиграммалары бик үткен; *остроумный ответ* — тапкыр җавап.

**ОСТРОУ'ХИЙ** — очлы колаклы; *остроухая рысь* — очлы колаклы селәүсен.

**ОСТРОХВО'СТЫЙ** — очлы койрыклы; *острохвостая птица* — очлы койрыклы кош.

**ОСТРУГА'ТЬ** *сов. обл.* — к. обстрогать.

**ОСТРУ'ГИВАТЬ** *несов. обл.* — к. остругать.

**ОСТРУ'ГИВАТЬСЯ** *несов. страд. обл.* — юнып чыгылу, ышкылап шомартып чыгылу.

**О'СТРЫЙ** — 1. үткен; *острый нож* — үткен пычак; 2. очлы, очлы башлы; *острая крыша* — очлы башлы түбә; *острый подбородок* — очлы ияк; 3. *перен.* үткен, зирәк;

*острые глаза* — үткен күзләр; *острый ум* — зирәк акыл, үткен акыл; 4. әче, борын яргыч; *острый вкус* — әче тәм; 5. *перен.* чәнечкеле, үткен, зәһәрле; *острая шутка* — зәһәрле шаярту; 6. көчле, каты; *острая форма ревматизма* — ревматизмның көчле формасы; 7. кискен, чиктән тыш кискен; *острое положение* — чиктән тыш кискен хәл. ◇ **Острый угол** *мат.*—кысынкы почмак. **Острый на язык** — үткен телле, әче телле.

**ОСТРЯ'К** *м.*, **ОСТРЯ'ЧКА** *ж.разг.* — тапкыр сүзле кеше, тапкыр сүзгә оста кеше.

**ОСТУ'ДА** *ж. обл. нар.-поэт.* — ара салкынаю, ара бозылу, ачуланышу, салкынаю, күнел кайту.

**ОСТУДИ'ТЬ** *сов.* — суыту.

**ОСТУЖА'ТЬ** *несов.* — к. остудить.

**ОСТУЖА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — суытылу.

**ОСТУПА'ТЬСЯ** *несов.* — к. оступиться.

**ОСТУПИ'ТЬСЯ** *сов.* — ялгыш басу; *оступился и вывихнул ногу* — ялгыш басып аягымны каймыктырдым (тайдырдым).

**ОСТЫВА'ТЬ** *несов.* — к. остыть.

**ОСТЫ'ЛЫЙ** *устар.* — 1. салкын; *остылый пот* — салкын тир; 2. *(постылый)* сөйкемсез, күңелсез.

**ОСТЫ'НУТЬ** *сов. простореч.* — к. остыть.

**ОСТЫ'ТЬ** *сов.* — 1. *(стать холодным)* суыну; 2. *перен.* басылу, салкынаю, күңел кайту; *гнев его еще не остыл* — аның ачуы басылмаган әле.

**ОСТЬ** *ж.* — кылчык (орлыкта һ. б.).

**ОСТЯКИ'** *мн.* (*ед.* остяк) — остяклар (Себердә яшәгән кайбер халыкларны, мәсәлән, хантыларны, электә шулай атаганнар).

**ОСТЯ'ЧКА** *ж.* — остяк хатын-кызы.

**ОСУДИ'ТЬ** *сов.* — 1. гаепләү, гаепләп карар чыгару; 2. яманлау, шелтәләү; 3. *книжн.* бетәргә хөкем итү, ...-ырга тиеш булу; *капитализм осуждён на гибель* — капитализм бетәргә хөкем ителгән. ◇ **Не осудите** *разг. устар.* — гаепкә алмагыз, гафу итегез.

**ОСУЖДА'ТЬ** *несов.* — к. осудить.

**ОСУЖДЕ'НИЕ** *ср.* — 1. *(строгое неодобрение)* начар дип табу; 2. *(обвинительный судебный приговор)* гаепләү, гаепләп карар чыгару.

**ОСУ'НУТЬСЯ** *сов. разг.* — ябыгу, бик ябыгу, суырылу; *он осунулся и побледнел совсем* — ул бик ябыккан да бөтенләй төсе киткән.

**ОСУША'ТЬ** *несов.* — к. осушить.

**ОСУША'ТЬСЯ** *несов. страд.* — киптерелү, корытылу.

**ОСУШИ'ТЕЛЬНЫЙ** *тех.* — киптерү...-ы, корыту...-ы; *осушительные мероприятия* — киптерү чаралары.

**ОСУШИ'ТЬ** *сов.* — 1. киптерү, корыту; *осушить болото*—сазлыкны киптерү; 2. эчеп бетерү, беткәнче эчү; *осушить стакан* — бер стакан эчеп бетерү. ◇ **Осушить глаза** — елаудан туктау. **Осушить слёзы** — кайгы-хәсрәтен җиңеләйтү, юату.

**ОСУЩЕСТВИ'МОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книжн.* — тормышка ашырылырлык булу.

**ОСУЩЕСТВИ'МЫЙ** *книжн.* — тормышка ашырырлык (ашырылырлык), булдыра алырлык, кулдан килерлек; *вполне осуществимые планы* — тулысынча тормышка ашырырлык планнар.

**ОСУЩЕСТВИ'ТЬ** *сов.* — тормышка ашыру, үтәү; *осуществить планы* — планнарны тормышка ашыру.

**ОСУЩЕСТВИ'ТЬСЯ** *сов.* — тормышка ашу, үтәлү; *осуществились все наши планы* — безнең бөтен планнарыбыз тормышка ашты.

**ОСУЩЕСТВЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. осуществить.

**ОСУЩЕСТВЛЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. осуществиться; 2. *страд.* тормышка ашырылу, үтәлү.

**ОСЧАСТЛИ'ВИТЬ** *сов.* — бәхетле итү.

**ОСЧАСТЛИ'ВЛИВАТЬ** *несов.* — к. осчастливить.

**ОСЫПА'ЕМОСТЬ** *ж. мн.* нет, *с.-х.* — коелучанлык, коелучан булу; *осыпаемость пшеницы* — бодайның коелучанлыгы.

**ОСЫ'ПАТЬ** и **ОБСЫ'ПАТЬ** *сов. разг.* — 1. өстенә сибү, сибеп чыгу, сибү; *осыпать снегом* — өстенә кар сибү; 2. күмү, каплау; *осыпать цветами* — чәчәккә күмү; 3. тарату; *осыпать кучу песка* — ком өемен тарату; 4. коюь; *яблоня осыпала листья* — алмагач яфракларын койган; 5. *перен. книжн.* күмеп ташлау, күмү, күп итеп бирү; *осыпать деньгами* — акчага күмү; 6. *перен.* яудыру; *осыпать упрёками* — шелтә яудыру. ◇ **Осыпать поцелуями** — кат-кат үбү.

**ОСЫПА'ТЬ** *несов.* — к. осыпать.

**ОСЫ'ПАТЬСЯ** *сов.* — 1. коелу, сибелү, коелып бетү; *цветы осыпались* — чәчәкләр коелган; *зёрна осыпались из колосьев* — ашлык бөртекләре башактан коелып беткән; 2. ишелү, ишелеп төшү; *насыпь осыпалась* — туфрак өеме ишелеп төшкән.

**ОСЫПА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. осыпаться; 2. *страд.* коеп төшерелү.

**О'СЫПЬ** *ж. геол.* — сибелмә (тау токымнарының җил йогынтысында таркалуыннан барлыкка килгән өем).

**ОСЬ** *ж.* — 1. күчәр; *вагонная ось* — вагон күчәре; 2. *перен. книжн. ритор.* үзәк; *ось вопроса* — мәсьәләнең үзәге.

**ОСЬМЕРИ'К** *м. обл.* — к. восьмерик.

**ОСЬМИ'НА** *ж. истор.* — осьмина (электә үлчәү берәмлеге — 105 литр).

**ОСЬМИНО'Г** *м. зоол.* — сигезаяк.

**ОСЬМО'Й** *устар. обл.* — к. восьмой.

**ОСЬМУ'ХА, ОСЬМУ'ШКА** *ж. устар. обл.* — к. восьмушка.

**ОСЯЗА'ЕМОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книжн.* — сизелә торган булу, сизелүчәнлек.

**ОСЯЗА'ЕМЫЙ** *книжн.* — 1. сизелә торган; 2. *перен.* сизелерлек; *осязаемые результаты* — сизелерлек нәтиҗәләр. ◇ **Едва осязаемый** — сизелер-сизелмәс.

**ОСЯЗА'НИЕ** *ср. мн.* нет — сизем, сизү, тойгы.

**ОСЯЗА'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книжн.* — сизелерлек булу.

**ОСЯЗА'ТЕЛЬНЫЙ** — 1. *только полн. формы* сизә торган, сизү ...-ы, тою ...-ы; *осязательные нервы* — тою нервлары; 2. *перен. книж.* сизелерлек, сизелеп тора торган; *осязательные результаты* — сизелерлек нәтиҗәләр.

**ОСЯЗА'ТЬ** *несов.*— 1. сизү, тою; 2. *перен. книж.* сизү, аңлау, төшенү.

**ОТ** *предлог* — 1. ...-дан; *от Горького плыли на пароходе* — Горькийдан пароход белән бардык; 2. ...-да; *письмо от пятого июля* — бишенче июльдә язылган хат; 3. ...-ы; *ножка от стола* — өстәл аягы; *пуговица от пиджака* — пиджак төймәсе; *ключ от чемодана* — чемодан ачкычы. ◇ **От силы** — күп дигәндә; *до города от силы тридцать километров* — шәһәргә хәтле күп дигәндә утыз километр булыр. **День ото дня** — көннән-көн. **Время от времени** — вакыт-вакыт. **Час от часу** — сәгать саен. **Год от году** — елдан-ел. **От всей души** — чын күңелдән. **Писать от руки** — кулдан язу. **В стихах молодого поэта очень многое от Маяковского** — яшь шагыйрьнең шигырьләрендә бик күп вәрсә Маяковский рухында язылган. **От зари до зари** — к. заря. **От мала до велика** — яше-карты, һәммәсе.

**ОТА'ВА** *ж. мн.* нет, *с.-х.*— курпы (чабып алганнан соң үскән үлән).

**ОТА'ВНЫЙ** *с.-х.*— курпы ...-ы; *отавное сено* — курпы печәне.

**ОТАКЕЛА'ЖИВАТЬ** *несов. мор.*— к. отакелажить.

**ОТАКЕЛА'ЖИТЬ** *сов. мор.*— такелажлау (судноны кирәк-яраклар белән тәэмин итү).

**ОТА'ПЛИВАТЬ** *несов.*— к. отопить.

**ОТА'ПЛИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— ягылу, ягып җылытылу.

**ОТА'ПТЫВАТЬ** *несов.*— к. отоптать.

**ОТАП'ТЫВАТЬСЯ** *несов. страд.*— таптап чыгылу (тирәли).

**ОТА'РА** *ж.*—сарык көтүе.

**ОТА'РЩИК** *м.*— сарык көтүчесе.

**ОТБА'ВИТЬ** *сов.*— киметү, кимәтә төшү; азайту, азайта төшү; *отбавить воды из ведра* — чиләктәге суны кимәтә төшү.

**ОТБАВЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. отбавить. ◇ **Хоть отбавляй** *разг.*— кирәгеннән артык, күп.

**ОТБАВЛЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — киметелү, азайтылу.

**ОТБА'ЛИВАТЬ** *несов.*— к. отболеть.

**ОТБАРАБА'НИТЬ** *сов.*— 1. барабан кагудан туктау; 2. *перен. разг.* начар уйнау, дыңгырдату, дыңгырдатып алу (музыка коралында); *отбарабанить вальс* — вальс дыңгырдатып алу; 3. *перен.* такылдап сөйләп чыгу, такылдап укып чыгу; *отбарабанить стихи* — такылдап шигырьләр укып чыгу.

**ОТБЕ'ГАТЬ** *сов.*— 1. (*перестать, кончить бегать*) йөгерүдән туктау, йөгереп йөрүдән туктау; 2. *разг.* йөгереп авырттырып бетерү; *отбегать пятки* — йөгереп үкчәләрне авырттырып бетерү.

**ОТБЕГА'ТЬ** *несов.*— к. отбежать.

**ОТБЕЖА'ТЬ** *сов.*— 1. йөгереп китү; *отбежать в сторону* — читкә йөгереп китү; 2. *устар.* качып китү; *отбежал в неизвестном направлении* — билгесез юнәлештә качып киткән.

**ОТБЕ'ЛИВАТЬ** *несов.*— к. отбелить.

**ОТБЕ'ЛИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— агартылу.

**ОТБЕЛИ'ТЬ** *сов.*— 1. агарту; *отбелить холст* — киндерне агарту; 2. *разг.* (*кончить белить*) агартып бетерү.

**ОТБЕ'ЛЬНЫЙ** *спец.*— агарту ...-ы; агарта торган; *отбельный цех* — агарту цехы; *отбельная земля* — агарта торган туфрак.

**ОТБЕ'ЛЬЩИК** *м.*, **ОТБЕ'ЛЬЩИЦА** *ж. спец.*—агартучы (эшче); *отбельщик кожи* — күн агартучы.

**ОТБЕСЕ'ДОВАТЬ** *сов. книж.*— сөйләшеп бетерү.

**ОТБЕСИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — җилкенүдән туктау, котырынудан туктау, тилереп йөрүдән туктау.

**ОТБИВА'ТЬ** *несов.*— к. отбить.

**ОТБИВА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. отбиться; 2. *страд.* сугып кайтарылу, кире кагылу, сугып кире җибәрелү; 3. *страд.* дәрте сүндерелү, теләге бетерелү; басып алыну; сугышып алыну, тартып алыну; биздерелү; үзенә каратылу; бәреп төшерелү, сындырып төшерелү; бәреп имгәтелү.

**ОТБИВНО'Й** *спец.* — таптау ...-ы; *отбивной молот* — таптау чүкече. ◇ **Отбивные котлеты**—итне суккалап йомшартып ясалган котлет.

**ОТБИРА'ТЬ** *несов.*— к. отобрать.

**ОТБИРА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — көчләп тартып алыну; сайлап алыну.

**ОТБИ'ТЬ** *сов.*— 1. кире кайтару, сугып кире кайтару, кире кагу; сугып кире җибәрү; *отбить мяч* — тупны сугып кире җибәрү; *отбить атаку* — атаканы кире кайтару; 2. (*заставить отступить*) чигенергә мәҗбүр итү; 3. *разг.* бетерү, күңелен кайтару; *отбить желание* — теләген бетерү; *отбить горечь* — ачысын кайтару (ачы тәмен бетерү); *отбить память* — хәтерен бетерү; 4. коткарып алу, йолып алу, сугышып кире кайтарып алу; *отбить пленных* — пленныйларны коткарып алу; *отбить оружие у противника* — дошманның коралын сугышып алу; 5. *разг.* биздерү; *отбил он их от дому своим высокомерием*—үзенең тәкәбберлеге белән ул аларны өеннән биздерде; 6. үзенә карату; *отбил он у меня девушку* — ул минем кызны үзенә каратты; 7. ватып төшерү, бәреп төшерү, сындырып төшерү; *отбить ручку у чайника* — чәйнекнең тоткасын ватып төшерү; 8. (*повредить, утомить ударами, толчками*) бәреп зәгыйфьләндерү, бәреп имгәтү, авырттырып бетерү; 9. сугу; *колокол отбил восемь ударов* — чаң сигез тапкыр сукты; 10. (*кончить бить*) сугудан туктау; 11. җеп сугу (тактага, бүрәнәгә туры сызык ясар өчен); *отбить линию мелом* — акбур белән җеп сугу; 12. *обл.* үлчәп аерып алу; *отбить участок земли* — җир участогын үлчәп

аерып алу; 13. таптау; *отбить косу* — чалгы таптау.

**ОТБИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. һөҗүмне кире кайтару; *отбиться от кавалерии* — кавалерия һөҗүмен кире кайтару; 2. котылу; *от этого человека ничем не отбиться* — бу кешедән берничек тә котылып булмый; 3. аерылып калу, аерылу; *корова отбилась от стада* — сыер көтүдән аерылып калган; *отбился от своих* — үзебезнекеләрдән аерылып калган; 4. сынып төшү, ватылып төшү; *носик чайника отбился* — чәйнекнең борыны сынып төшкән. ◇ **Отбиться от рук** *разг.* — юлдан язу, азып-тузып йөрү, сүз тыңламый башлау, буйсынмый башлау.

**ОТБЛАГОДАРИ'ТЬ** *сов.* — 1. *книж.* рәхмәт әйтү, рәхмәт белдерү; *отблагодарил меня и распрощался* — миңа рәхмәт әйтте дә саубуллашты; 2. (*вознаградить за услугу*) яхшылыкка каршы яхшылык итү, бүләкләү.

**ОТБЛАЖИ'ТЬ** *сов. разг.* — киреләнүдән туктау, усэүзләнүдән туктау.

**О'ТБЛЕСК** *м.* — чагылма, чагылыш, чагылма яктылык, ут шәүләсе; *отблески пламени* — ялкын чагылышы.

**ОТБЛЕ'СКИВАТЬ** *несов.* — 1. (*давать отблеск*) чагылу, чагылып яктылык бирү; 2 *редко* ялтырап тору; *море отблескивает синим цветом* — диңгез зәңгәр булып ялтырап тора.

**ОТБЛЕСТЕ'ТЬ** *сов.* — ялтырамый башлау, ялтыраудан туктау.

**ОТБЛИСТА'ТЬ** *сов.* — 1. (*перестать блестеть*) ялтырамый башлау; 2. матурлыгын югалту; *она давно уже отблистала* — ул күптән инде үзенең матурлыгын югалткан.

**ОТБО'Й** *м.* — 1. *только ед. воен.* отбой, отбой сугу (берәр нәрсәнең бетүен белдереп); 2. (*о разъединении телефонных абонентов*) отбой бирү. ◇ **Отбою нет** *разг.* — котылыр хәл юк, чиктән тыш күп. **Бить отбой** — к. бить.

**ОТБО'ЙКА** *ж. мн.* нет, *горн.* — вату, ватып төшерү; *отбойка каменного угля* — ташкүмер вату.

**ОТБО'ЙНЫЙ** *горн.* — ташкүмер вату ...-ы; ташкүмер вата торган; *отбойный молот* — ташкүмер вата торган чүкеч.

**ОТБОЛЕ'ТЬ** *сов. разг.* — 1. (*перестать болеть*) терелеп җитү, савыгу, савыгып җитү; 2. *простореч.* төшү; *ноготь отболел* — тырнак төште.

**ОТБО'Р** *м. мн.* нет — 1. (*действие*) к. отобрать; 2. *биол.* сайланыш; *естественный отбор* — табигый сайланыш; *искусственный отбор* — ясалма сайланыш.

**ОТБО'РНЫЙ** — 1. сайланма, иң яхшы; *отборный товар* — иң яхшы товар; 2. *книж.* (*очень вежливый, изысканный*) бик ягымлы, нәзакәтле; 3. *разг.* әшәке, оятсыз; *отборная ругань* — оятсыз сүгенү.

**ОТБОРОНИ'ТЬ** *сов. разг.* — тырмалап бетерү, тырмалап чыгу.

**ОТБО'РЩИК** *м.*, **ОТБО'РЩИЦА** *ж. спец.* — сортларга аеручы, сортларга бүлүче.

**ОТБОЯ'РИВАТЬСЯ** *несов. разг. фам.* — к. отбояриться.

**ОТБОЯ'РИТЬСЯ** *сов. разг фам.* — хәйләләп котылу, ычкыну (күңел теләмәгән эштән); *отбояриться от неприятного дела* — күңелсез эштән хәйләләп котылу.

**ОТБРАКОВА'ТЬ** *сов. спец.* — бракка чыгару (сайлап алып).

**ОТБРАКО'ВКА** *ж. спец.* — 1. *только ед.* к. отбраковать; 2. (*отбракованная вещь*) бракка чыгарылган әйбер.

**ОТБРАКО'ВЫВАТЬ** *несов. спец.* — к. отбраковать.

**ОТБРАКО'ВЫВАТЬСЯ** *несов. страд. спец.* — бракка чыгарылу.

**ОТБРА'НИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — әрләшү, тиргәшү, тиргәшеп җавап кайтару, сүгенеп җавап кайтару.

**ОТБРАНИ'ТЬ** *сов. разг.* — 1. бик нык орышу, шелтәләү, тиргәү, орышып ташлау, тиргәп ташлау; 2. (*прекратить бранить*) орышудан туктау, тиргәүдән туктау.

**ОТБРАНИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. ызгышып туктау, тиргәшеп туктау, әрепләшеп туктау, сүгешеп туктау; 2. (*ответить бранью и ругательством*) тиргәшеп җавап бирү, әрепләшеп җавап бирү, сүгенеп җавап кайтару.

**ОТБРА'СЫВАТЬ** *несов.* — к. отбросить.

**ОТБРА'СЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — читкә ыргытылу, алып ташлану.

**ОТБРЕСТИ'** *сов.* — әкрен генә китү, әкрен генә китеп бару, көчкә-көчкә генә атлап китү; *стадо отбрело от леса* — көтү әкрен генә урман яныннан китте.

**ОТБРИВА'ТЬ** *несов.* — к. отбрить.

**ОТБРИВА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. отбриться; 2. *страд.* кырып бетерелү; кисеп ташлану; кырып ташлану.

**ОТБРИ'ТЬ** *сов.* — 1. (*кончить брить*) кырып бетерү; 2. *разг.* (*отрезать, сбрить*) кисеп ташлау, кыркып ташлау; 3. *перен. разг. фам.* (*резко ответить*) кырт кисеп җавап бирү.

**ОТБРИ'ТЬСЯ** *сов.* — кырынып бетү.

**ОТБРОДИ'ТЬ** *сов. разг.* — әчеп туктау, кабарып туктау, күпереп туктау; *квас отбродил* — квас әчеп туктады.

**ОТБРО'С** *м.* — ташландык, чүп-чар, калдыклар. ◇ **Отбросы общества** — әдәм актыклары, җәмгыятьнең бозык, җинаятьчел элементлары.

**ОТБРОСА'ТЬ** *сов.* — 1. *разг.* ...-га алып ташлау; *отбросай камни в канаву* — ташларны канауга алып ташла; 2. (*кончить бросать*) ташлаудан туктау, ыргытудан туктау.

**ОТБРОСА'ТЬСЯ** *сов. простореч.* — ыргытышып туктау, ыргытышудан туктау.

**ОТБРО'СИТЬ** *сов.* — 1. алып ташлау, читкә алып ташлау; *отбросить камень с дороги* — ташны юлдан алып ташлау; 2. *воен.* чигенергә мәҗбүр итү, чигендерү, куып җибәрү; *противника отбросили за реку* — дошманны елганың аръягына чигендерделәр; 3. кире кагу, кабул итмәү, ташлау; *отбросить вредную теорию* — зарарлы теорияне кабул итмәү; 4. читкә тайпылу;

*лошадь отбросила задом* — ат арт санын читкә тайпылдырды; 5. чагылдыру (мәсәлән, су өсте кояш нурларын); 6. күләгә төшерү; күләгә төшү; *дуб отбросил тень* — имән агачының күләгәсе төшкән.

**ОТБРЯ'КАТЬ** *сов. просторец.* — 1. *(кончить брякать)* шалтыратудан туктау, челтерәтүдән туктау; 2. *(высказать, не стесняясь)* турыдан-туры әйтү, әйтеп салу.

**ОТБУЗОВА'ТЬ** *сов. просторец.* — тукмаклап ташлау, дөмбәсләп ташлау.

**ОТБУКСИРОВА'ТЬ** *сов. спец.* — буксирга алып илтеп кую.

**ОТБУКСИРОВА'ТЬСЯ** *сов. спец.* — буксирга тагылып китү; *отбуксироваться с мели* — сай җирдән буксирга тагылып китү.

**ОТБУРИ'ТЬ** *сов. горн.* — бораулап бетерү; *отбурить скважину* — нефть коесын бораулап бетерү.

**ОТБУРЛИ'ТЬ** *сов.* — ургылып чыгудан туктау (чишмә); быкырдап кайнаудан туктау (су); ярсып дулкынланудан туктау (диңгез).

**ОТБУ'ЧИВАТЬ** *несов. тех.* — к. отбучить.

**ОТБУ'ЧИВАТЬСЯ** *несов. страд. тех.* — 1. селтедә кайнатылу (мәсәлән, кер); 2. йомшартылу (иләү алдыннан тиренең махсус эремәләргә салып йомшартылуы).

**ОТБУ'ЧИТЬ** *сов. тех.* — 1. селтедә кайнатып алу (мәсәлән, керне); 2. йомшартып алу (тирене иләү алдыннан махсус эремәләргә салып).

**ОТБУШЕВА'ТЬ** *сов.* — туктау, давылланып туктау; *буря отбушевала* — давыл туктады.

**ОТБЫВА'ТЬ** *несов.* — к. отбыть.

**ОТБЫ'ТЬ** *сов.* — 1. *офиц.* китү, чыгып китү; *делегаты отбыли в Москву* — делегатлар Москвага киттеләр; 2. *офиц.* срогын тутыру, срогын тутырып кайту; *отбыть военную службу* — гаскәри хезмәтнең срогын тутырып кайту; 3. *просторец.* котылу; *сколько ни жить, а смерти не отбыть (поговорка)* — күпме яшәсәң дә, үлемнән котыла алмассың.

**ОТВА'ГА** *ж. мн.* нет — батырлык, кыюлык, гайрәт.

**ОТВА'ДИТЬ** *сов. разг.* — биздерү, аеру, ташлату; *отвадить от курения* — тәмәке тартудан биздерү.

**ОТВА'ДИТЬСЯ** *сов. разг.* — бизү, ташлау.

**ОТВА'ЖИВАТЬ** *несов. разг.* — к. отвадить.

**ОТВА'ЖИВАТЬСЯ** I *несов. разг.* — 1. к. отвадиться; 2. *страд.* биздерелү.

**ОТВА'ЖИВАТЬСЯ** II *несов.* — к. отважиться.

**ОТВА'ЖИТЬСЯ** *сов.* — батырчылык итү, тәвәккәллек итү; *он отважился переплыть глубокую реку* — ул тирән елганы йөзеп чыгарга батырчылык итте.

**ОТВА'ЖНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — батырлык, кыюлык, йөрәклелек, гайрәтлелек.

**ОТВА'ЖНЫЙ** *книж.* — батыр, кыю, йөрәкле, гайрәтле; *отважный воин* — батыр сугышчы.

**ОТВА'Л** *м.* — 1. *только ед. (действие)* к. отвалить; 2. сука калагы; 3. *спец.* өем (чокыр казыганда читкә өелгән җир); 4. *горн.* ташландык руда, эшкәртергә ярамый торган тау токымы. ◇ До отвала или до отвалу *(наесться, накормить) разг.* — гарык булганчы, чиксез күп, туйганчы (ашау, ашату).

**ОТВА'ЛИВАТЬ** I *несов.* — к. отвалить. ◇ Отваливай *(пов. накл.)* — бәйләнмә миңа, кит яныннан, кит моннан.

**ОТВА'ЛИВАТЬ** II *несов.* — к. отвалять 1.

**ОТВА'ЛИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. отвалиться; 2. *страд.* актарылу, әйләндереп салыну; *пласты земли отваливаются плугом* — җир катламнары сабан белән әйләндереп салына (ягъни сабан җир катламын әйләндереп сала).

**ОТВАЛИ'ТЬ** *сов.* — 1. читкә аударып ташлау, читкә этәреп ташлау, аударып читкә этү; *отвалить камень* — ташны читкә этеп, аударып ташлау; *отвалить глину* — балчыкны читкә этәреп ташлау; 2. *разг. фам.* чыгарып салу, чыгарып бирү; *отвалил на расходы сотню* — расходка йөз сум чыгарды да бирде; 3. *мор.* кузгалып китү; *пароход отвалил в три часа* — пароход сәгать өчтә кузгалып китте.

**ОТВАЛИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. кубып төшү, кубу; *штукатурка отвалилась* — штукатурка кубып төшкән; 2. *просторец.* китеп бару, читкә китү, китү; *пустые покупатели скоренько отвалились* — акчасыз кешеләр тиз генә китеп бардылар; 3. *спорт.* артка калу; *он отвалился с четвертого круга* — ул дүртенче кругтан башлап артка калды; 4. *просторец.* туеп туктау; *младенец отвалился от груди* — бала имүдән туеп туктады.

**ОТВА'ЛЬНЫЙ** — 1. кузгалып китү ...-ы; *отвальный свисток* — кузгалып китүгә сызгырту; 2. *разг. фам. устар.* саубуллашу ...-ы; *отвальная вечеринка* — саубуллашу кичәсе.

**ОТВА'ЛЬЩИК** *м.*, **ОТВА'ЛЬЩИЦА** *ж.* *спец.* — ишеп төшерүче (эшче); *отвальщик соли* — тоз ишеп төшерүче.

**ОТВАЛЯ'ТЬ** *сов.* — 1. басып кую; *десять пар валенок отвалял* — ун кием киез итек басып куйган; 2. *разг. фам.* ничек итте шулай эшләп ташлау, эштерөштер китерү; *дело мигом отвалял* — эшне бик тиз эштер-өштер китерде.

**ОТВА'Р** *м.* — 1. *только ед. спец. (действие)* к. отварить; 2. шулпа, саркынды; *рисовый отвар* — дөге саркындысы.

**ОТВА'РИВАТЬ** *несов.* — к. отварить.

**ОТВА'РИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. отвариться; 2. *страд.* кайнатып алыну.

**ОТВАРИ'ТЬ** *сов.* — 1. кайнатып алу (пешерү түгел); *отварить овощи* — яшелчәне кайнатып алу; 2. *спец.* утта кыздырып аерып алу, утта кыздырып кубарып алу; *отварить рельс* — рельсны утта кыздырып кубарып алу.

**ОТВАРИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. пешү, пешеп җитү, кайнавы җитү; *мясо отварилось* — ит пешеп җиткән; *грибы отварились* — гөмбәләрнең кайнавы җиткән; 2. *спец.* ку-

был төшү, кубу (кыздырылу сәбәпле, кыздырылу аркасында).

**ОТВАРНО'Й** и **ОТВА'РНЫЙ** — пешкән, кайнатылган, кайнатып пешерелгән; кайнаган; *отварная вода* — кайнаган су (суытылган); *отварное мясо* — пешкән ит. ◇ Отварный картофель — суда пешерелгән бәрәңге.

**ОТВЕВА'ТЬ** *несов.* — к. отвеять.

**ОТВЕВА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — җилгәреп аерылу.

**ОТВЕ'ДАТЬ** *сов. разг.* — 1. тәмен татып карау, кабып карау; 2. (*испытать*) тату. (дөньяның) ачысын-төчесен татып карау.

**ОТВЕДЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — 1. читкә юнәлдерү, читкә алып китү; *отведение рек* — елгаларны читкә юнәлдерү; 2. бүлеп бирү; *отведение участков земли* — җир участокларын бүлеп бирү.

**ОТВЕ'ДЫВАТЬ** *несов. разг.* — к. отведать.

**ОТВЕ'ДЫВАТЬСЯ** *несов. разг. страд.* — тәме татып каралу, татылу, кабып каралу.

**ОТВЕЗТИ'** *сов.* — 1. илтеп кую, илтү (атка, машинага һ. б. утыртып); *отвезти товарища в город* — иптәшне шәһәргә илтеп кую; 2. читкә алып китү, алып китеп ташлау; *отвезти мусор от дороги* — чүпчарны юлдан читкә илтеп ташлау.

**ОТВЕ'ИВАТЬ** *несов.* — к. отвеять.

**ОТВЕ'ИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. *просторе*ч. к. отвеяться; 2. *страд.* җилгәреп аерылу.

**ОТВЕКОВА'ТЬ** *сов. обл.* — гомер үткәрү; *она в девках отвековала* — ул кыз булып гомерен үткәрде.

**ОТВЕРГА'ТЬ** *несов.* — кире кагу, кабул итмәү, инкарь итү; *отвергать помощь* — ярдәмне кабул итмәү.

**ОТВЕРГА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — кире кагылу, кабул ителмәү, инкарь ителү.

**ОТВЕ'РГНУТЬ** *сов. книж.* — к. отвергать.

**ОТВЕРДЕВА'ТЬ** *несов.* — к. отвердеть.

**ОТВЕРДЕ'ЛЫЙ** *книж.* — каткан, катып калган.

**ОТВЕРДЕ'НИЕ** *ср.* — 1. *только ед.* (*действие*) к. отвердеть; 2. (*твёрдое, затвердевшее место*) каткан урын, катыланган җир.

**ОТВЕРДЕ'ТЬ** *сов.* — кату, катылану, катып калу; *опухоль отвердела* — шеш катыланган.

**ОТВЕ'РЖЕНЕЦ** *м. книж.* — читкә кагылган кеше, читләтелгән кеше.

**ОТВЕ'РЖЕННЫЙ** *книж.* — читкә кагылган, читләтелгән, хокуксыз (капиталистик җәмгыятьтә); *отверженный человек* — читкә кагылган кеше.

**ОТВЕРЗА'ТЬ** *несов. книж. ритор. поэт. устар.* — ачу; *отверзать объятия* — кочак ачу.

**ОТВЕРЗА'ТЬСЯ** *несов. книж. ритор. поэт. устар.* — ачылу.

**ОТВЕ'РЗТИСЬ** *сов. книж. ритор. поэт. устар.* — к. отверзаться.

**ОТВЕ'РЗТЬ** *сов. книж. ритор. поэт. устар.* — к. отверзать.

**ОТВЕРНУ'ТЬ** *сов.* — 1. борып алу, борып чыгару; *отвернуть винт* — винтны борып алу; 2. борып ачу, ачу, бору; *отвернуть кран* — кранны ачу; 3. читкә карау, йөзен читкә таба бору, читкә бору; *отвернул лицо* — йөзен читкә борды; 4. бөгеп кую, кайтарып кую; *отвернуть полу* — чабуны кайтарып кую; 5. *разг.* каерып өзү, боргалап өзү, каерып алу; *отвернуть кукле руку* — боргалап, курчакның кулын каерып алу.

**ОТВЕРНУ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. борылып чыгу; *гайка отвернулась* — гайка борылып чыккан; 2. ачылу, борылып ачылу; *кран отвернулся* — кран ачылган; 3. кайтарылу; *одеяло отвернулось* — юрган кайтарылган; 4. борылу; *отвернуться в сторону* — читкә борылу, читкә карау; 5. *перен.* читләшү, бәйләнешне өзү; *все от него отвернулись* — барысы да аңардан читләште.

**ОТВЕ'РСТИЕ** *ср.* — тишек, авыз, юл; *отверстие в стене* — стена тишеге, стенадагы тишек.

**ОТВЕ'РСТИСЬ** *сов.* — к. отверзтись.

**ОТВЕ'РСТЫЙ** *книж. ритор. поэт. устар.* — ачык.

**ОТВЕРТЕ'ТЬ** *сов. разг.* — 1. *простореч.* к. отвернуть 1; 2. *простореч.* к. отвернуть 5; 3. *фам.* боргалап талдыру, боргалап авырттыру, боргалап имгәтү; *отвертеть руку* — боргалап кулны имгәтү.

**ОТВЕРТЕ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. *простореч.* к. отвернуться 1; 2. *простореч.* каерылу, каерылып чыгу; *ручка отвернулась* — тотка каерылып чыккан; 3. *разг.* (*уклониться, отделаться от чего-н.*) котылу, хәйләләп котылу (унайсыз хәлдән).

**ОТВЁРТКА** *ж.* — 1. *только ед. простореч.* (*действие*) к. отвернуть 1; 2. отвёртка, шөреп боргыч.

**ОТВЁРТЫВАТЬ** *несов.* — к. отвернуть.

**ОТВЁРТЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. отвернуться; 2. *страд.* борып алыну, борып чыгарылу; борып ачылу; кайтарып куелу.

**ОТВЕ'С** *м.* — 1. *тех.* шакул (герле җеп); 2. текә яр; 3. *физ.* асма.

**ОТВЕ'СИТЬ** *сов.* — 1. үлчәп бирү; *отвесить кило сахару* — бер кило шикәр үлчәп бирү; 2. *спец.* вертикаль юнәлешне билгеләү; 3. *простореч. устар.* (*нанести удар*) салып җибәрү, сугып җибәрү. ◇ Отвесить поклон *книж.* — баш ию, иелеп сәлам бирү.

**ОТВЕ'СНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — текәлек.

**ОТВЕ'СНЫЙ** — текә; *отвесные скалы* — текә кыялар.

**ОТВЕСТИ'** *сов.* — 1. илтү, илтеп кую; *отвести ребёнка домой* — баланы өйгә илтеп кую; 2. *воен.* чигерү, күчерү; *отвести войска на заранее приготовленные позиции* — гаскәрләрне алдан хәзерләнгән позицияләргә күчерү; 3. *перен.* читкә алып китү; *отвести стадо от дороги* — көтүне юлдан читкә алып китү; 4. читкә юнәлдерү; *отвести реку от города* — елганы шәһәрдән читкә юнәлдерү; 5. *книж.* кире кагу; *отвести обвинение* — гаепне кире кагу; 6. *офиц.* чыгару, төшерү, алу; *отве-*

*сти кандидатуру* — кандидатурасын төшерү; 7. аерып бирү, бүлеп бирү, билгеләү; *отвести участок земли* — жир участогын аерып бирү. ◇ **Отвести душу** — күңелне бушату, эч серләрен сөйләү. ◇ **Отвести глаза** *кому разг.* — игътибарын икенче нәрсәгә юнәлдерү. **Отвести от соблазна** *перен.* — коткыдан саклап калу.

**ОТВЕ'Т** *м.* — җавап. ◇ **Семь бед — один ответ** — мең бәлагә бер җавап.

**ОТВЕТВИ'ТЬ** *сов. спец.* — тармакландыру, ботакландыру.

**ОТВЕТВИ'ТЬСЯ** *сов.* — тармаклану, ботаклану.

**ОТВЕТВЛЕ'НИЕ** *ср.* — 1. үренте, ботак, үсенте; 2. тармак; *железнодорожная магистраль имеет много ответвлений* — тимер юл магистраленең бик күп тармаклары бар.

**ОТВЕТВЛЯ'ТЬ** *несов. спец.* — к. ответвить.

**ОТВЕТВЛЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. ответвиться; 2. *страд.* тармакландырылу, ботакландырылу.

**ОТВЕ'ТИТЬ** *сов.* — җавап бирү, җавап кайтару. ◇ **Ответить урок** — дәресне сөйләп бирү.

**ОТВЕ'ТНЫЙ** — җавап...-ы, җавап бирү...-ы; *ответное письмо* — җавап хаты. ◇ **Ответный выстрел** — атуга каршы ату.

**ОТВЕ'ТСТВЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет — җаваплылык. ◇ **Привлечь к судебной ответственности** — суд җаваплылыгына тарту, судка бирү, судка тарту.

**ОТВЕ'ТСТВЕННЫЙ** — 1. җаваплы; *ответственный редактор* — җаваплы редактор; 2. мөһим; *ответственный вопрос* — мөһим мәсьәлә.

**ОТВЕ'ТСТВОВАТЬ** *сов.* и *несов. книж. ритор. устар.* — к. отвечать.

**ОТВЕ'ТЧИК** *м.*, **ОТВЕ'ТЧИЦА** *ж. офиц.* — җавапчы, җавапка тартылучы, җавап бирергә тиешле кеше; *за всех он не ответчик* — бар кеше өчен дә ул җавап бирергә тиеш түгел.

**ОТВЕЧА'ТЬ** *сов.* и *несов.* — 1. җавап бирү, җавап кайтару; 2. (*соответствовать*) ярау, туры килү; *отвечать техническим правилам* — техника кагыйдәләренә туры килү; 3. җаваплы булу; *отвечать за сохранность имущества* — милекнең саклануына җаваплы булу.

**ОТВЕ'ШАТЬ** *сов.* — үлчәп бетерү.

**ОТВЕ'ШИВАТЬ** I *несов.* — к. отвесить.

**ОТВЕ'ШИВАТЬ** II *несов.* — к. отвешать.

**ОТВЕ'ШИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — үлчәп бирелү.

**ОТВЕ'ЯТЬ** *сов.* — 1. (*закончить веяние*) җилгәреп бетерү; 2. (*веянием отделить*) җилгәреп аеру.

**ОТВЕ'ЯТЬСЯ** *сов. простореч.* — к. отвеять 1.

**ОТВИВА'ТЬ** *несов.* — к. отвить.

**ОТВИ'ЛИВАТЬ** *несов. разг.* — к. отвильнуть.

**ОТВИЛЬНУ'ТЬ** *сов. разг.* — хәйләләп котылу, хәйләләп котылып калу, юлын табып качу; *отвильнуть от ответа* — җавап бирүдән хәйләләп котылу.

**ОТВИНТИ'ТЬ** *сов.* — борып чыгару, борып алу; *отвинтить гайку* — гайканы борып алу.

**ОТВИНТИ'ТЬСЯ** *сов.* — борылып чыгу; *гайка отвинтилась* — гайка борылып чыккан.

**ОТВИ'НЧИВАТЬ** *несов.* — к. отвинтить.

**ОТВИ'НЧИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. отвинтиться; 2. *страд.* борып алыну, борып чыгарылу.

**ОТВИСА'ТЬ** *несов.* — салынып тору, салыну.

**ОТВИ'СЛЫЙ** — салынкы, салынып төшкән, салынып тора торган; *старый пиджак с отвислыми карманами* — кесәләре салынып төшкән иске пиджак.

**ОТВИ'СНУТЬ** *сов.* — салынып төшү.

**ОТВИ'ТЬ** *сов.* — 1. (*закончить витьё*) ишеп бетерү, үреп бетерү; 2. (*развивая, отделить*) сүтеп алу, сүтеп аеру, сүтү (үрелгәнне, ишелгәнне).

**ОТВЛЕКА'ТЬ** *несов.* — к. отвлечь.

**ОТВЛЕКА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. отвлечься; 2. *страд.* игътибары икенче бер нәрсәгә юнәлдерелү, фикере башка нәрсәгә юнәлдерелү.

**ОТВЛЕЧЕ'НИЕ** *ср. книж.* — 1. *только ед.* (*действие*) к. отвлечь; 2. *филос.* к. абстракция.

**ОТВЛЕЧЁННОСТЬ** *ж. книж.* — абстрактлык.

**ОТВЛЕЧЁННЫЙ** — абстракт; *отвлечённое понятие* — абстракт төшенчә. ◇ **Отвлечённое число** *мат.* — исемсез сан. **Отвлечённое имя существительное** — абстракт исем.

**ОТВЛЕ'ЧЬ** *сов.* — 1. читкә юнәлдерү, башка нәрсәгә юнәлдерү; *отвлечь внимание* — фикерне башка нәрсәгә юнәлдерү; 2. йомшарту, киметү, җиңеләйтү; *горчичник отвлёк боль* — горчичник авыртуны җиңеләйтте; 3. *книж.* (*выделить из всей совокупности*) аерып алу, абстрактлаштыру.

**ОТВЛЕ'ЧЬСЯ** *сов.* — фикерне читкә юнәлдерү, читкә китү; *отвлечься от темы* — темадан читкә китү.

**ОТВО'Д** *м.* — 1. *только ед.* (*действие*) к. отвести; 2. *офиц.* (*заявление об отстранении, протест*) ризасызлык белдерү, отвод ясау, кире кагу; 3. *тех.* тармак, отвод; *отвод кабеля* — кабельнең тармагы; 4. *разг.* (*в санях*) урәчә. ◇ **Для отвода глаз** *разг.* — күз буяу өчен. **Громовой отвод** *устар.* — яшен кайтаргыч.

**ОТВОДИ'ТЬ** I *несов.* — к. отвести.

**ОТВОДИ'ТЬ** II *сов. разг.* — йөртеп туктау, йөртеп бетерү.

**ОТВОДИ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. илтеп куелу; чигерелү, күчерелү; читкә алып кителү, читкә юнәлдерелү; чыгарылу, төшерелү; бүлеп бирелү; 2. күчереп утыртылу.

**ОТВО'ДНЫЙ** *спец.* — 1. читкә чыгара торган; *отводный канал* — читкә чыгара торган канал; 2. отвод белдерә торган, ризасызлык белдерә торган; риза булмауны белдерә торган.

**ОТВО'ДОК** *м.* — 1. *биол.* бөре ботак

(үсемлек үрчетү өчен алына торган ботак); 2. *с.-х. биол.* нәсел, токым.

**ОТВОЕВА'ТЬ** *сов.* — 1. (*отобрать, приобрести путём войны*) сугышып алу, сугышып кайтарып алу; 2. (*кончить воевать*) сугышны бетерү; 3. *разг.* сугышта үткәрү; *три года отвоевали* — өч ел сугышта үткәрдек.

**ОТВОЁВЫВАТЬ** *несов.* — к. отвоевать 1, 2.

**ОТВОЁВЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — сугышып алыну, сугышып кайтарып алыну.

**ОТВОЗИ'ТЬ** I *несов.* — к. отвезти.

**ОТВОЗИ'ТЬ** II *сов. разг.* — 1. ташып бетерү; 2. *перен. вульг.* (*избить, вываля́ть*) тукмап ташлау, кыйнап ташлау; пычратып бетерү, буяп бетерү.

**ОТВОЗИ'ТЬСЯ** I *несов. страд.* — илтеп куелу; читкә алып ташлану.

**ОТВОЗИ'ТЬСЯ** II *сов. разг.* — шаярудан туктау, кайнашудан туктау.

**ОТВО'ЗЧИК** *м.*, **ОТВО'ЗЧИЦА** *ж. спец.* — ташучы, йөкче, йөк ташучы; *отвозчик песка на золотых приисках* — алтын приискаларында ком ташучы.

**ОТВОЛА'ЖИВАТЬ** *несов. спец.* — к. отволожить.

**ОТВОЛА'ЖИВАТЬСЯ** *несов. страд. спец.* — суда йомшартылу, җебетелү, җебетеп йомшартылу (мәсәлән, тире, күн).

**ОТВОЛО'ЖИТЬ** *сов. спец.* — җебетү, чылату (эшкәртү процессында); *отволожить кожу* — күнне җебетү.

**ОТВОЛОЧИ'ТЬ** *сов. просторeч.* — 1. (*волоча, оттащить*) сөйрәп илтеп ташлау, естерәп илтеп ташлау; 2. (*отколотить*) тукмап ташлау, дөмбәсләп ташлау, кыйнап ташлау; 3. (*кончить волочить проволоку*) тимер чыбыкны сузып бетерү; 4. (*изготовить волочением*) сузып тимер чыбык ясау.

**ОТВОЛО'ЧЬ** *сов. просторeч.* — к. отволочить 1.

**ОТВОРА'ЧИВАТЬ** *несов.* — к. отворотить.

**ОТВОРА'ЧИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. отворотиться; 2. *страд.* тәгәрәтеп читкә алып ташлану; кайтарып куелу.

**ОТВОРИ'ТЬ** *сов.* — ачу (ишекне, капканы). ◇ Отворить кровь *мед. устар.* — банка салу (авыру кешегә).

**ОТВОРИ'ТЬСЯ** *сов.* — ачылу; *дверь отворилась* — ишек ачылды.

**ОТВОРО'Т** *м.* — 1. *только ед.* (*действие*) к. отворотить; 2. кайтарма куныч; кайтарма яка; *сапоги с отворотом* — кайтарма кунычлы итек; 3. *обл. нар.-поэт.* (*в поверьях*) сихер кайтаргыч, бөти, тылсым.

**ОТВОРОТИ'ТЬ** *сов.* — 1. *разг.* читкә алып ташлау, тәгәрәтеп читкә алып ташлау; *отворотить камень* — ташны тәгәрәтеп читкә алып ташлау; 2. *просторeч.* кисеп бирү, зур итеп кисеп бирү; *отвороти-ка мне... хлебца* (Даль) — миңа икмәк кисеп бир әле; 3. *разг.* к. отвернуть 2, 3, 4, 5; 4. *просторeч.* күңел кайту; *отворотило от еды* — ашамлыктан (аштан) күңел кайтты.

**ОТВОРОТИ'ТЬСЯ** *сов. просторeч.* — к. отвернуться.

**ОТВОРО'ТНЫЙ** *обл. нар.-поэт.* (*в поверьях*) — сихергә каршы, зәхмәткә каршы; *отворотное зелье* — сихергә каршы дару.

**ОТВОРО'ЧАТЬ** *сов. разг.* — әйләндерүдән туктау.

**ОТВОРЯ'ТЬ** *несов.* — к. отворить.

**ОТВОРЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. отвориться; 2. *страд.* ачылу.

**ОТВРАТИ'ТЕЛЬНЫЙ** — җирәнгеч, шакшы, чирканыч, бик начар; *отвратительная внешность* — чирканыч кыяфәт; *отвратительная погода* — бик начар һава (көн).

**ОТВРАТИ'ТЬ** *сов. книж.* — 1. *устар.* (*направить в сторону*) читкә бору, бөтән юнәлеш бирү; 2. булдырмый калу, булдырмау; *отвратить беду* — бәлане булдырмау; 3. *устар.* тотып калу; *отвратить от дурного поступка* — әшәкелектән тотып калу.

**ОТВРА'ТНЫЙ** *разг. фам.* — к. отвратительный.

**ОТВРАЩА'ТЬ** *несов. книж.* — к. отвратить.

**ОТВСЮ'ДУ** *нареч.* — к. отовсюду.

**ОТВЫКА'ТЬ** *несов.* — к. отвыкнуть.

**ОТВЫ'КНУТЬ** *сов.* — күңел кайту, ташлау, бизү; *отвык от курения* — тәмәкене ташлады, тәмәке тартуны ташлады.

**ОТВЫ'ТЬ** *сов. разг.* — улаудан туктау, улап туктау.

**ОТВЫ'ЧКА** *ж. мн.* нет, *просторeч.* — бизү, күңел кайту.

**ОТВЯЗА'ТЬ** *сов.* — чишеп алу, чишеп җибәрү, бәйдән ычкындыру.

**ОТВЯЗА'ТЬСЯ** *сов.* — 1. бәйдән ычкыну; *лошадь отвязалась* — ат бәйдән ычкынган; 2. чишелү; *верёвка отвязалась* — бау чишелгән; 3. *разг. фам.* (*перестать приставать, надоедать*) бәйләнүдән туктау, бәйләнмәү (кешегә); 4. *разг. фам.* котылу; *надо отвязаться от него* — аңардан котылырга кирәк.

**ОТВЯ'ЗЫВАТЬ** *несов.* — к. отвязать.

**ОТВЯ'ЗЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. отвязаться; 2. *страд.* чишеп алыну, чишеп җибәрелү, бәйдән ычкындырылу.

**ОТГАДА'ТЬ** *сов.* — табышмакның җавабын табу; белү, әйтү; *отгадай, в каком ухе звенит* — әйт, кайсы колагым шаулый.

**ОТГА'ДКА** *ж.* — 1. табышмакның җавабы, табышмакның җавабын табу; 2. җавабы табылу, сере ачылу, сере чишелү; *неожиданная отгадка* — көтмәгәндә сере ачылу.

**ОТГА'ДЧИК** *м.*, **ОТГА'ДЧИЦА** *ж. разг.* — табышмак табучы, сер чишүче, уйлап табучы, төш юраучы; *я не отгадчик снов* — мин төш юраучы түгел.

**ОТГА'ДЫВАТЬ** *несов.* — к. отгадать.

**ОТГА'ДЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — табышмакның җавабы табылу; сере ачылу.

**ОТГА'ЩИВАТЬ** *несов. разг.* — к. отгостить.

**ОТГИБА'ТЬ** *несов.* — к. отогнуть.

**ОТГИБА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. отогнуться; 2. *страд.* бөгелү; кайтарылу.

**ОТГЛАГО'ЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *грам.*— фигыльдән ясалганлык.

**ОТГЛАГО'ЛЬНЫЙ** *грам.* — фигыльдән ясалган; *отглагольное существительное*— фигыльдән ясалган исем.

**ОТГЛА'ДИТЬ** *сов.* — үтүкләү, үтүкләп бетерү.

**ОТГЛА'ДИТЬСЯ** *сов.* — 1. үтүкләнү; *брюки хорошо отгладились* — чалбар яхшы үтүкләнгән; 2. (*кончить гладить*) үтүкләп бетерү.

**ОТГЛА'ДЫВАТЬ** *несов. разг.* — к. отглодать.

**ОТГЛА'ДЫВАТЬСЯ** *несов. страд. разг* — кимерелеп бетү (мәсәлән, сөяк).

**ОТГЛА'ЖИВАТЬ** *несов.* — к. отгладить.

**ОТГЛА'ЖИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. отгладиться 1; 2. *страд.* үтүкләнү, шомартылу.

**ОТГЛА'ТЫВАТЬ** *несов. разг.* — к. отглотнуть.

**ОТГЛОДА'ТЬ** *сов. разг.* — 1. кимереп бетерү (мәсәлән, сөякне); 2. кимереп өзү, кимереп төшерү.

**ОТГЛОТНУ'ТЬ** *сов. разг.* — йотып җибәрү, бик аз гына эчеп алу.

**ОТГНИВА'ТЬ** *несов.* — к. отгнить.

**ОТГНИ'ТЬ** *сов.* — череп төшү.

**ОТГОВА'РИВАТЬ** *несов.*— к. отговорить.

**ОТГОВА'РИВАТЬСЯ** *несов.* — сылтау табу, сылтап котылу, сылтаулар табып котылырга тырышу, сылтау табып баш тарту (эштән); *отговариваться недосугом* — вакыт юклыкка сылтап, котылырга тырышу.

**ОТГОВОРИ'ТЬ** *сов.* — үгетләп тыю, үгетләп тыеп калу; *отговорить от поездки в город* — үгетләп, шәһәргә барудан тыеп калу.

**ОТГОВОРИ'ТЬСЯ** *сов.* — к. отговариваться.

**ОТГОВО'РКА** *ж.* — сылтау, юк-бар сәбәп (игътибарга алынмаслык сәбәп).

**ОТГОВО'РЩИК** *м. разг.* — тыючы, кирегә димләүче.

**ОТГОЛО'СОК** *м.* — 1. яңгыравык, яңгырык (яңгырап кайтып ишетелгән тавыш); 2. *перен.* (*последствие, отзвук какого-н. события*) нәтиҗә, эз (берәр вакыйганың, хәлнең).

**ОТГО'Н** *м. спец.* — 1. *только ед.* к. отгонка; 2. куудан калган продукт; *спиртные отгоны* — спирт куудан калган продуктлар.

**ОТГО'НКА** *ж. мн.* нет, *спец.* — куу; аерып чыгару; *отгонка масел из нефти*— нефтьтән майлар куу (майлар аерып чыгару).

**ОТГОНЯ'ТЬ** I *несов.* — 1. к. отогнать; 2. *спец.* (*производить отгонку*) куу (мәсәлән, нефтьтән майлар һ. б.).

**ОТГОНЯ'ТЬ** II *сов. обл.* — куудан туктау, (мәсәлән, спирт турында).

**ОТГОРА'ЖИВАТЬ** *несов.* — к. отгородить.

**ОТГОРА'ЖИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. отгородиться; 2. *страд.* киртәләп алыну, бүлеп алыну.

**ОТГОРЕВА'ТЬ** *сов. разг.* — кайгырудан туктау, кайгырып туктау, хәсрәтләнүдән туктау, хәсрәт чигүдән туктау.

**ОТГОРЕ'ТЬ** *сов.* — 1. янудан туктау; 2. (*отвалиться, перегорев*) янып төшү; 3. *разг.* (*кончить гореть в игре*) гөрләүдән туктау (гөрле-качышлы уенда).

**ОТГОРОДИ'ТЬ** *сов.* — киртәләп алу, бүлеп алу, бүлеп кую; *отгородить часть комнаты шкафом* — бүлмәнең бер өлешен шкаф белән бүлеп кую.

**ОТГОРОДИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. бүленү, киртәләнү; *отгородиться от соседей забором* — күршеләрдән койма белән бүленү; 2. *перен.* читләшү; *отгородиться от друзей* — дуслардан читләшү.

**ОТГОСТИ'ТЬ** *сов. разг.* — кунак булып китү; *они два дня отгостили* — алар ике көн кунак булып киттеләр.

**ОТГРАНИ'ТЬ** *сов.* — 1. кырлап чыгу; *огранить топаз* — топазны кырлап чыгу; 2. (*кончить гранить*) кырлап бетерү.

**ОТГРАНИ'ЧИВАТЬ** *несов. книж.* — чикләү, чикләп чыгу, чик куеп аеру.

**ОТГРАНИ'ЧИВАТЬСЯ** *несов. страд. книж.* — чикләнү, чикләп чыгылу, чик куеп аерылу.

**ОТГРАНИ'ЧИТЬ** *сов. книж.* — к. отграничивать.

**ОТГРАФИ'ТЬ** *сов.* — графалап чыгу, графалар сызып чыгу.

**ОТГРАФЛЯ'ТЬ** *несов. спец.* — к. отграфить.

**ОТГРАФЛЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.спец.* — графалап чыгылу, графалар сызылу.

**ОТГРЕБА'ТЬ** *несов.* — 1. көрәп ташлау; *отгребать снег* — карны көрәп ташлау; 2. тырма белән читкә алып ташлау; *отгребать сено от дороги*—печәнне тырма белән юлдан читкә алып ташлау; 3. *разг.* казып чыгару; *олень отгребает мох* — болан мүкне казып чыгара; 4. ишеп кузгалып китү, ишеп китү; *отгребать от берега* — ишеп яр буеннан кузгалып китү.

**ОТГРЁБЩИК** *м. спец.* — көрәүче; *отгрёбщик угля в шахтах* — шахтада ташкүмер көрәүче.

**ОТГРЕМЕ'ТЬ** *сов.* — 1. күкрәп туктау, күкрәүдән туктау; *гром отгремел* — күк күкрәп туктады; 2. гөрселдәүдән туктау; күкрәве тыну, тыну; *пушки отгремели* — туплар күкрәве тынды, туплар тындылар.

**ОТГРЕСТИ'** *сов.*— к. отгребать.

**ОТГРЕСТИ'СЬ** *сов. разг.* — ишеп кузгалып китү, ишеп китү; *отгрестись от берега* — ишеп яр буеннан кузгалып китү.

**ОТГРО'ХАТЬ** *сов. разг.* — гөрселдәүдән туктау, гөрселдәми башлау; *пушки отгрохали* — пушкалар гөрселдәми башладылар.

**ОТГРОХОТА'ТЬ** *сов.* — к. отгрохать.

**ОТГРУЖА'ТЬ** *несов.* — к. отгрузить.

**ОТГРУЖА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. отгрузиться; 2. төяп җибәрелү; 3. йөк киметелү.

**ОТГРУЗИ'ТЬ** *сов.* — 1. төяп җибәрү; *совхоз отгрузил в Ленинград сто тонн мяса* — совхоз Ленинградка йөз тонна ит төяп җибәрде; 2. (*снять, отбавить груз*) йөкне киметү; 3. (*кончить грузить*) төяп бетерү.

**ОТГРУСТИ'ТЬ** *сов. разг.* — ямансылаудан туктау, сагынмый башлау, эч пошмый башлау.

**ОТГРЫЗА'ТЬ** *несов.* — к. отгрызть.

**ОТГРЫЗА'ТЬСЯ** *несов. разг.* — к. отгрызться.

**ОТГРЫ'ЗТЬ** *сов.* — 1. чәйнәп өзү, кимереп өзү, тешләп өзү, тешләп алу; 2. чәйнәүдән туктау кимерүдән туктау.

**ОТГРЫ'ЗТЬСЯ** *сов. разг. фам.* — тиргәшкә тиргәш белән җавап кайтару, тиргәшү, әрләшү.

**ОТГУДЕ'ТЬ** *сов.* — гүелдәп туктау, гүелдәүдән туктау; *отгудели гудки* — гудоклар гүелләүдән туктадылар.

**ОТГУ'ЛИВАТЬ** *несов.* — к. отгулять.

**ОТГУ'ЛИВАТЬСЯ** *несов.* — к. отгуляться.

**ОТГУ'ЛЬНЫЙ** *разг.* — эштән буш; *отгульный день* — эштән буш көн.

**ОТГУЛЯ'ТЬ** *сов.* — 1. (*вернуться с прогулки*) күңел ачып йөрүдән туктау, күңел ачып йөреп кайту; 2. күңелле үткәрү, типтерү; *славно отгулял я в своё время* — типтереп калдым мин заманында; 3. *обл.* симертү, көрәйтү (терлекне көтүлектә йөртеп).

**ОТГУЛЯ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. күңелле үткәрү; 2. симерү, көрәю (мал басуда, кырда йөреп); *лошадь хорошо отгулялась за лето* — ат җәй көне басуда йөреп симергән (көрәйгән).

**ОТМЕ'СТКА** *ж.*: **в отместку** *разг.* — үч итеп.

**ОТМЕТА'ТЬ** *несов.*— к. отмести.

**ОТМЕТА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— себереп бетерелү, себереп ташлану.

**ОТМЕ'ТИНА** *ж. простореч.*— кашка; *жеребёнок с отметиной на лбу* — кашка колын. ◇ **Без отметины** *разг.* — тигез, чиста, зыянсыз, бозык урыны юк.

**ОТМЕ'ТИТЬ** *сов.*— 1. билгеләү, билге кую, тамгалау, тамга салу; *отметить деревья зарубкой* — агачларга киртләчләп тамга салу; 2. *книж.* күреп алу, танып алу; *сразу отметил в толпе знакомого* — халык арасында шунда ук танышын күреп алды; 3. әйтеп китү, күрсәтеп китү, искә алып китү; *докладчик отметил хорошую работу коллектива* — докладчы коллективның яхшы эшләве турында әйтеп китте; *отметить недостатки в работе* — эштәге кимчелекләрне күрсәтеп китү; 4. язып алу, билге кую; *отметить опоздавших* — соңга калучыларны язып алу; 5. *офиц.* йорт кенәгәсеннән төшерү; *отметить жильца* — квартирда торучыны йорт кенәгәсеннән төшерү. ◇ **Отметить премией** — премия бирү.

**ОТМЕ'ТИТЬСЯ** *сов. офиц.*— 1. (*зарегистрироваться*) язылу; 2. (*выписаться из домовой книги*) йорт кенәгәсеннән төшү.

**ОТМЕ'ТКА** *ж.*— 1. *только ед. разг.* (*действие*) к. отметить 1, 4, 5; 2. (*знак*) билге, тамга; 3. (*балл*) билге, отметка (мәктәптә); 4. (*регистрация, проверка*) тикшерү, регистрация ясау; 5. *геодез.* билге.

**ОТМЕ'ТЧИК** *м. спец.*— билге куючы, билгеләүче (эшче).

**ОТМЕЧА'ТЬ** *несов.*— к. отметить.

**ОТМЕЧА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. отметиться; 2. *страд.* сизелү, беленү, күренү; *отмечаются крупные успехи в технике* — техникада зур уңышлар барлыгы күренә.

**ОТМИНА'ТЬ** *несов.*— к. отмять.

**ОТМИНА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— йомшартылу, изелү.

**ОТМИРА'ТЬ** *несов.*— к. отмереть.

**ОТМОКА'ТЬ** *несов.*— к. отмокнуть.

**ОТМО'КНУТЬ** *сов.* — юешләнеп җебү, юешләнеп йомшару.

**ОТМОЛА'ЧИВАТЬ** *несов.* — к. отмолотить.

**ОТМОЛА'ЧИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. *простореч.* к. отмолотиться; 2. *страд.* сугып бетерелү (ашлык турында).

**ОТМОЛИ'ТЬ** *сов. разг. устар.* — к. замолить.

**ОТМОЛИ'ТЬСЯ** *сов.* — гыйбадәт кылып бетерү, гыйбадәт кылудан туктау.

**ОТМОЛОТИ'ТЬ** *сов.* — 1. сугып бетерү; *отмолотить всю рожь* — барлык арышны сугып бетерү; 2. ашлык сугып алу; *отмолотили два дня* — ике көн ашлык сугып алдык; 3. ашлык сугу эшләрен тәмамлау.

**ОТМОЛОТИ'ТЬСЯ** *сов. простореч.* — к. отмолотить 3.

**ОТМОЛО'ТЬ** *сов.* — 1. тарттырып бетерү (ашлыкны); 2. (*смолоть известное количество*) тарттырып алу (берникадәр); 3. тарттырудан туктау.

**ОТМОЛО'ТЬСЯ** *сов. простореч.* — тарттырып бетерү (ашлыкны).

**ОТМОЛЧА'ТЬСЯ** *сов.* — юри җавап бир-

мәү, эндәшмичә калу, җавап бирми калу, җавап бирүдән баш тарту.

**ОТМОРА'ЖИВАТЬ** *несов.* — к. отморозить.

**ОТМОРА'ЖИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — өшетелү, туңдырылу.

**ОТМОРО'ЗИТЬ** *сов.* — өшетү, туңдыру.

**ОТМОТА'ТЬ** *сов.* — 1. сүтү, сүтеп алу; *отмотать бинт* — бинтны сүтеп алу; 2. *разг.* (*мотая, утомить*) сүтә-сүтә ардырып-талдырып бетерү; 3. (*перестать мотать*) чорнаудан (чорнап) туктау.

**ОТМОТА'ТЬСЯ** *сов.* — 1. сүтелү (йомгактан җеп); 2. к. отмотать 3; 3. *простореч. фам.* (*уклониться от чего-н. неприятного*) хәйләләп котылу, хәйләләп баш тарту.

**ОТМОЧИ'ТЬ** *сов.* — 1. (*отклеить, намочив*) юешләп куптарып алу, чылатып куптарып алу; 2. *спец.* җебетү; *отмочить кожу* — күнне җебетү; 3. *перен. простореч. фам.* әйтеп ташлау, эшләп ташлау; *отмочить глупость* — ахмаклык эшләп ташлау.

**ОТМО'ЧНЫЙ** *спец.* — җебетелгән, юешләтелгән; *отмочный вес шкур* — җебетелгән тиреләрнең авырлыгы.

**ОТМСТИ'ТЬ** *сов. книж. устар.* — к. отомстить.

**ОТМУТИ'ТЬ** *сов. спец.* — к. отмучивать.

**ОТМУ'ЧИВАТЬ** *несов. спец.* — су белән юдырып аеру; *отмучивать золото от песку* — су белән юдырып комнан алтынны аеру.

**ОТМУ'ЧИВАТЬСЯ** *несов. страд. спец.* — су белән юдырып аерылу.

**ОТМУ'ЧИТЬ** *сов. разг.* — интектерүдән туктау, газаплаудан туктау.

**ОТМУ'ЧИТЬСЯ** *сов. разг.* — котылу (интегүдән, газаплanudан).

**ОТМЩА'ТЬ** *несов. книж. устар.* — үч алу, үч кайтару.

**ОТМЩЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж. устар.* — к. отомстить.

**ОТМЫВА'ТЬ** *несов.* — к. отмыть.

**ОТМЫВА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. отмыться; 2. *страд.* юып алыну, юып төшерелү, юып тазартылу.

**ОТМЫ'КАТЬ** *сов. обл. разг.* — 1. талкып бетерү; *отмыкать лён* — җитенне талкып бетерү; 2. михнәт чигүдән котылу; *отмыкать горе* — михнәт чигүдән котылу.

**ОТМЫКА'ТЬ** *несов.* — к. отомкнуть.

**ОТМЫ'КАТЬСЯ** *сов. разг.* — интегүдән котылу, михнәт чигүдән котылу.

**ОТМЫКА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. отомкнуться; 2. *страд.* ачылу, алыну; ычкындырылу.

**ОТМЫ'ТЬ** *сов.* — 1. (*удалить грязь*) юып тазарту, юып алу, юып төшерү; 2. (*кончить мыть*) юып бетерү; 3. *простореч.* ашау; *вода отмыла берег* — су ярны ашаган.

**ОТМЫ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. (*очиститься при мытье*) юып тазартылу, юып алыну, юып төшерелү; юып бетерелү; 2. *простореч.* (*кончить мыться*) юынып бетү.

**ОТМЫ'ЧКА** *ж.* — 1. *только ед. простореч.* (*действие*) к. отмыкать; 2. отмычка (һәртөрле йозакны ача торган ачкыч).

**ОТМЯКА'ТЬ** *несов.* — к. отмякнуть.

**ОТМЯ'КНУТЬ** *сов.* — йомшау, җебү.

**ОТМЯ'ТЬ** *сов.* — 1. йомшарту, изеп йомшарту, йомшарта төшү; *отмять глину* — балчыкны изеп йомшарту; 2. *разг. фам.* кысрыклап чыгару; *его отмяли к стене* — аны кысрыклап, стена янына чыгарганнар.

**ОТНА'ШИВАТЬ** *несов. разг.* — к. относить II.

**ОТНА'ШИВАТЬСЯ** *несов. разг. страд.* — киеп туздырып бетерелү.

**ОТНЕ'КАТЬСЯ** *сов. раз.* — к. отнекиваться.

**ОТНЕ'КИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — риза булмау, баш тарту, киреләнү, ык-мык итү.

**ОТНЕСТИ'** *сов.* — 1. (*неся, доставить*) илтү, илтеп бирү, илтеп тапшыру, илтеп кую; 2. алып китү; *лодку отнесло течением вниз* — су көймәне түбәнгә агызып алып киткән; 3. күчерү, күчереп кую; *отнести забор на пять метров дальше* — койманы биш метрга арырак күчерү; 4. *разг.* кисеп төшерү, чабып төшерү; *отнес полчерепа медведю топором* — аюның яртш башын балта белән чабып төшергән; 5. (хисабына) кертү, исәпләү; *отнести происшествие к числу самых обычных* — вакыйганы иң гади вакыйгалар хисабына кертү; 6. кертү, булган дип карау, исәпләү; *отнести это событие к XV веку* — бу вакыйганы XV йөздә булган дип карау; 7. кайтарып калдыру, *ошибку следует отнести к его небрежности* — хатаны аның игътибарсызлыгына кайтарып калдырырга кирәк. ◇ **Отнести расходы на** *чей-либо* **счёт** *офиц.* — расходларны бирәр кеше хисабына күчерү.

**ОТНЕСТИ'СЬ** *сов.* — 1. күрсәтү, карау, караштa булу; *отнестись высокомерно* — тәкәбберлек күрсәтү; *врач внимательно отнёсся к больному* — врач авыруны зур игътибар белән карады; 2. *офиц. устар.* (*обратиться в официальном порядке*) мөрәҗәгать итү; 3. *устар.* үз фикерен әйтү, бәя бирү, фикердә булу; *отнестись о ком-н. с уважением* — берәр кеше турында яхшы фикердә булу (зурлап, хөрмәтләп сөйләү).

**ОТНИЗА'ТЬ** *сов.* — 1. (тезелгәнне) кире чыгару, аерып алу; *отнизать несколько бусин* — берничә сәйләнне бөртеген кире чыгару; 2. (*закончить низание*) тезеп бетерү, тезеп туктау (җепкә).

**ОТНИ'ЗЫВАТЬ** *несов.* — к. отнизать.

**ОТНИКЕЛИРОВА'ТЬ** *сов.* — никельләп чыгу, никель йөгертеп чыгу.

**ОТНИМА'ТЬ** *несов.* — к. отнять.

**ОТНИМА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. отняться; 2. *страд.* тартып алыну, көчләп алыну, аерып алыну.

**ОТНОСИ'ТЕЛЬНО** *нареч. книж.* — 1. чагыштырмача, яхшы ук, азмы-күпме; *опыт прошёл относительно удачно* — тәҗрибә уңышлы үтте; 2. *в знач. предлога с род. п.* турысында, карата; *относительно хода дела ещё ничего нельзя сказать* — эшнең барышы турында хәзергә берни дә әйтеп булмый әле.

**ОТНОСИ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — чагыштырмалы булу, чамалы булу. ◇ **Теория относительности** — чагыштырмалылык теориясе, нисбәтлек теориясе.

**ОТНОСИ'ТЕЛЬНЫЙ** — 1. *научн.* чагыштырма; *относительная влажность* — чагыштырма дымлылык; 2. *книж.* шартлы, чикле, чамалы; *доброта его относительная* — аның яхшылыгы чамалы; 3. *грам.* нисби; *относительное прилагательное* — нисби сыйфат.

**ОТНОСИ'ТЬ** I *несов.* — к. отнести.

**ОТНОСИ'ТЬ** II *сов. разг.* — туздырып бетерү, кими башлау (тузып беткән өс киемен, аяк киемен һ. б.).

**ОТНОСИ'ТЬСЯ** I *несов.* — 1. к. отнестись; 2. *ст ад.* илтеп куелу, илтелү, илтеп бирелү; алып кителү, күчерелү; 3. бәйләнешле булу; *это к делу не относится* — моның эшкә бәйләнеше юк; 4. *мат.* мөнәсәбәттә булу.

**ОТНОСИ'ТЬСЯ** II *сов. разг.* — тузып бетү, искереп бетү (аяк киеме, өс киеме турында); *сапоги уже относились* — итекләр тузып беткән инде.

**ОТНОЧЕВА'ТЬ** *сов. разг.* — кунып чыгу.

**ОТНОШЕ'НИЕ** *ср. книж.* — 1. *только ед. (действие)* к. отнестись 1; 2. бәйләнеш, мөнәсәбәт, мөгамәлә, аралашу, караш; *отношение между двумя величинами* — ике зурлык арасындагы үзара бәйләнеш; 3. *офиц. (деловая бумага)* отношение, эш кәгазе. ◇ **По отношению к вам** — сезгә карата, сезнең турыда. **В этом отношении** — бу яктан. **Во всех отношениях** — төрле яктан, һәр яктан.

**ОТНЫ'НЕ** *нареч. книж. устар. ритор.* — бүгеннән алып, бүгенге көннән, бүгенге көннән алып, хәзердән алып, моннан соң; *отныне я вам не слуга* — бүгенге көннән мин сезгә хезмәтче түгел.

**ОТНЮ'ДЬ** *нареч. книж.* — бер дә, һич, бөтенләй, һич тә; *он отнюдь не такого мнения* — ул бөтенләй андый фикердә түгел.

**ОТНЯ'ТЬ** *сов.* — 1. *(насильно взять)* көчләп алу, тартып алу; 2. алу; *работа отняла много времени* — эш бик күп вакытны алды; 3. *разг.* аерып алу, аеру, алып кую; *отнять заслонку от печи* — мичнең капкачын алып кую; 4. кисү, кисеп алу; *отнять ногу* — аякны кисү; 5. *разг.* алу; *от десяти отнять пять* — уннан бишне алу. ◇ **Отнять жизнь** — үтерү.

**ОТНЯ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. калу, ...-сыз калу, хәрәкәт итми башлау, йөрми башлау; *у него отнялись ноги* — аның аяклары йөрми башлады, ул аяксыз калды; 2. *страд.* көчләп алыну, тартып алыну.

**ОТО** *предлог* — к. от.

**ОТОБЕ'ДАТЬ** *сов.* — 1. *(кончить обедать)* төшке ашны ашап бетерү; 2. *устар.* ашка килеп китү; *приходите отобедать* — ашка килеп китегез.

**ОТОБРАЖА'ТЬ** *несов.* — к. отобразить.

**ОТОБРАЖА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. отобразиться; 2. *страд.* сурәтләндерелү, гәүдәләндерелү, чагылдырылу.

**ОТОБРАЖЕ'НИЕ** *ср.* — 1. *только ед. (действие)* к. отобразить; 2. тасвир; *верное отображение* — дөрес тасвир.

**ОТОБРАЗИ'ТЬ** *сов.* — сурәтләндерү, гәүдәләндерү, чагылдыру; *писатель отобразил в своих произведениях новый быт* — язучы үзенең әсәрләрендә яңа тормышны чагылдырган.

**ОТОБРАЗИ'ТЬСЯ** *сов.* — сурәтләнү, гәүдәләнү, чагылу.

**ОТОБРА'ТЬ** *сов.* — 1. алу, кире алу, кайтарып алу; *отобрать билеты у пассажиров* — пассажирларның билетларын алу; 2. сайлап алу; *отобрать лучшие яблоки* — иң яхшы алмаларны сайлап алу; 3. *офиц. устар. (собрать путём опроса)* сорашып язып алу, сорашып протоколга язу.

**ОТОВА'РИВАТЬ** *несов. спец.* — к. отоварить.

**ОТОВА'РИВАТЬСЯ** *несов. страд. спец.* — товар белән тәэмин ителү, товар бирелү.

**ОТОВА'РИТЬ** *сов. спец.* — товар белән тәэмин итү, товар бирү; *отоварить договор* — договор буенча товар белән тәэмин итү.

**ОТОВСЮ'ДУ** *нареч.* — һәр яктан, һәр урыннан; *отовсюду торопливо бежали люди* (М. Горький) — һәр яктан ашыгып кешеләр йөгерә иде.

**ОТОГНА'ТЬ** *сов.* — 1. куып җибәрү; *отогнать собаку* — этне куып җибәрү; 2. баштан чыгарып ташлау, юк итү; *отогнать грустные мысли* — кайгылы уйларны баштан чыгарып ташлау; 3. *спец.* куып чыгару, куу; *отогнать скипидар* — скипидар куу.

**ОТОГНУ'ТЬ** *сов.* — 1. турайтып кую, төзәйтеп кую (бөгелгәнне); *отогнуть угол страницы* — битнең бөгелгән почмагын турайтып кую; 2. кайтарып кую; сызгану; *отогнул рукав и сел писать* — җиңен кайтарып куйды да язарга утырды.

**ОТОГНУ'ТЬСЯ** *сов.* — тураю, төзәю.

**ОТОГРЕВА'ТЬ** *несов.* — к. отогреть.

**ОТОГРЕВА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. отогреться; 2. *страд.* җылытылу.

**ОТОГРЕ'ТЬ** *сов.* — 1. җылыту; *отогреть руки* — кулларны җылыту; 2. *перен. (приютить)* сыендыру, урнаштыру, ягымлы чырай күрсәтү.

**ОТОГРЕ'ТЬСЯ** *сов.* — җылыну; *отогреться у печки* — мич янында җылыну.

**ОТОДВИГА'ТЬ** *несов.* — к. отодвинуть.

**ОТОДВИГА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. отодвинуться; 2. *страд.* этәреп җибәрелү; еракарак күчерелү; кичектерелү.

**ОТОДВИ'НУТЬ** *сов.* — 1. *(двигая, переместить)* этәреп кую; 2. *перен.* кичектерү, соңгарту; *отодвинуть поездку на месяц* — китүне (баруны) бер айга кичектерү.

**ОТОДВИ'НУТЬСЯ** *сов.* — 1. *(подвинуться в сторону)* күчү, читкәрәк китү; 2. *перен. разг.* кичектерелү, соңгартылу; *срок отодвинулся на два дня* — срок ике көнгә кичектерелде.

**ОТОДРА'ТЬ** *сов. разг.* — 1. *(оторвать, отделить)* кубарып алу, өзеп алу, каезлап алу; 2. *(высечь)* кыйнап ташлау, суктыру. ◇ **Отодрать за уши** — колагын тарту, ко-

лагын бору. Отодрать за волосы — чәчтән тарту, чәчен йолыккалау.

**ОТОДРА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — кубып төшү, өзелеп төшү; *подмётки отодрались* — олтаннары кубып төшкән.

**ОТОЖДЕСТВИ'ТЬ, ОТОЖДЕСТВЛЯ'ТЬ, ОТОЖДЕСТВЛЯ'ТЬСЯ** — к. отожествить и т. д.

**ОТОЖЕСТВИ'ТЬ** *сов.* — тиңләштерү, бер дип карау, икесе дә бер дип тану, бердәй дип тану, тиң итеп күрү; *ошибочно отожествить два различных явления* — берберсенә охшамаган ике күренешне ялгыш тиң итеп карау.

**ОТОЖЕСТВЛЯ'ТЬ** *несов. книж.* — к. отожествить.

**ОТОЖЕСТВЛЯ'ТЬСЯ** *несов. страд. книж.* — бердәй дип танылу, тиң итеп каралу, икесе дә бер дип танылу, тиңләштерелү.

**ОТОЗВА'ТЬ** *сов.* — 1. чакырып алу; *отозвать в сторону для разговора* — сөйләшү өчен читкә чакырып алу; 2. кайтару, чакырып кайтару; *отозвать посла* — илчене кайтару.

**ОТОЗВА'ТЬСЯ** *сов.* — 1. җавап кайтару, җавап бирү; *она не отозвалась* — ул җавап кайтармады; 2. *(высказать своё мнение)* фикерен әйтү, карашын әйтү; 3. тәэсир итү; *ночная работа может вредно отозваться на здоровье* — төнге эшнең сәламәтлеккә начар тәэсир итүе мөмкин.

**ОТОЙТИ'** *сов.* — 1. китү; *он встал и отошёл к стене* — ул торды да стена янына китте; *поезд отошёл в три часа* — поезд сәгать өчтә китте; 2. *воен.* чигенү; *батальон отошёл на новые позиции* — батальон яңа позицияләргә чигенде; 3. читкә китү; *отойти от темы* — темадан читкә китү; 4. читләшү, ераклашу; *отойти от старых друзей* — иске дуслардан ераклашу; 5. кубу, аерылу, читкә китү; *штукатурка отошла от стены* — штукатурка стенадан купкан; *крышка ссохлась и отошла от ящика* — ящикның капкачы коргаксып читкә киткән; 6. юып бетерелү, юылу; *пятно на платье отошло в стирке* — күлмәкнең табы юганда беткән; 7. язылу; *ноги занемели и не могут отойти* — аякларым оеганнар да языла алмыйлар; 8. *(очнуться, опомниться)* аңына килү, һушка килү; 9. *спец.* кимү; *при помоле зерна от него много отойдёт* — тарттырганда орлык бик күп кимер; 10. *устар.* үтү, узу; *лето отошло* — җәй үтте; 11. үлү, үлеп китү; *больной тихо отошёл* — авыру тын гына үлеп китте; 12. *устар. (уйти со службы)* эштән чыгу, хезмәтне ташлау. ◇ **Отойти ко сну** — йокыга китү. **Отойти в прошлое** — онытылу, искерү (гореф-гадәтләр, йолалар турында). **Отошло от сердца** — тынычланып калдым. **Дом отошёл к сыну** — йорт улына тиде. **Отойти в вечность** *перен. устар.* — үлү.

**ОТОЛГА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — ялганлап котылу; *попался, да отолгался* — эләккән иде дә ялганлап котылды.

**ОТОМКНУ'ТЬ** *сов.* — 1. *(отпереть замкнутое)* ачу (бикләгән әйберне); 2. ычкындыру, алу; *отомкнуть штык от винтовки* — винтовкадан штыкны алу.

**ОТОМКНУ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. ачылу; *замок отомкнулся* — йозак ачылды; 2. ычкыну; *штык отомкнулся* — штык ычкынды.

**ОТОМСТИ'ТЬ** *сов.* — үч алу, үч кайтару.

**ОТОМЩА'ТЬ** *несов. книж. устар.* — к. отомстить.

**ОТОПИ'ТЕЛЬНЫЙ** *спец.* — ягу ...-ы, җылыту ...-ы; *отопительный сезон* — ягу сезоны; *отопительная система* — җылыту системасы.

**ОТОПИ'ТЬ** *сов.* — җылыту, ягып җылыту; *отопить большой дом* — зур йортны ягып җылыту.

**ОТОПЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. отопить.

**ОТОПЛЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — җылытылу, ягып җылытылу.

**ОТОПРЕВА'ТЬ** *несов. разг.* — к. отопреть.

**ОТОПРЕ'ТЬ** *сов. разг.* — 1. тирләү; *окна отопрели* — тәрәзә пыялалары тирләгән; 2. кубып төшү (юешлектән); *краска отопрела* — буяу (юешлектән) кубып төшкән.

**ОТОРА'ЧИВАТЬ** *несов.* — кайма тоту, кайма тотып чыгу, кырпу тоту.

**ОТОРА'ЧИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — кайма тотылу, кырпу тотылу.

**ОТО'РВАННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — ялгызлык, бәйләнеш юклык, аерылганлык.

**ОТОРВА'ТЬ** *сов.* — 1. өзү, өзеп алу; *оторвать рукава* — җиңнәрне өзеп алу; 2. ертып алу; *оторвать листок из блокнота* — блокноттан бер бит кәгазь ертып алу; 3. *(резко отнять)* кинәт тартып алу; 4. аеру; *война оторвала его от родных* — сугыш аны туганнарыннан аерды; 5. *разг.* туктату, аеру; *оторвать от работы* — эштән туктату; *его не оторвёшь от книги* — аны китаптан аера алмассың. ◇ **Не мог оторвать глаз** — күреп туя алмады.

**ОТОРВА'ТЬСЯ** *сов.* — 1. өзелү, өзелеп төшү; *листок оторвался от ветки* — яфрак ботагыннан өзелеп төшкән; 2. туктау, бүленү, туктап тору; *оторваться от работы* — эштән туктау, эштән бүленү; 3. аерылу; *оторваться от массы* — массадан аерылу; 4. *воен. (потерять связь)* элемтәне югалту; 5. *авиац.* (җирдән) күтәрелеп китү; *самолёт оторвался от земли* — самолёт җирдән күтәрелеп китте.

**ОТОРЖА'ВЕТЬ** *сов. спец.* — тутыгып өзелеп төшү.

**ОТОРОПЕ'ЛЫЙ** *разг.* — каушаган, каушап калган, аптырап калган; *оторопелый взгляд* — аптырап калган караш.

**ОТОРОПЕ'ТЬ** *сов.* — каушау, каушап калу, аптырап калу; *оторопел, увидев его* — аны күргәч аптырап калды.

**О'ТОРОПЬ** *ж. мн.* нет, *разг.* — каушау, каушап калу, аптырау.

**ОТОРОЧИ'ТЬ** *сов.* — к. оторачивать.

**ОТОРО'ЧКА** *ж.* — кырпу, кайма, тасма (берәр нәрсәнең читенә тотыла торган).

**ОТОСЛА'ТЬ** *сов.* — 1. җибәрү; *отослать письмо* — хат җибәрү; 2. *(заставить уйти)* куып җибәрү; 3. *(рекомендовать навести справку)* чыганак күрсәтү; 4. *(рекомен-*

*довать обратиться к кому-н.*) (кемгә яки кәя) мерәҗәгать итәргә киңәш бирү.

**ОТОСПА'ТЬ** *сов.* — йоклау, йоклап тую; *ты отоспал своё* — син үзеңә тиешлене йокладың инде.

**ОТОСПА'ТЬСЯ** *сов.* — туйганчы йоклау, йокы туюю, йокы туйдыру.

**ОТОТКНУ'ТЬ** *сов. простореч.* — ачу, бөкесен алу; *ототкнуть бочку* — мичкәнең бөкесен алу.

**ОТОХО'ТИТЬ** *сов. простореч.* — биздерү, ташлату, гайрәтен кайтару; *отохотить от шалостей* — шаяруны ташлату.

**ОТОХО'ТИТЬСЯ** *сов. разг.* — ауга йөрми башлау, ауга йөрүдән туктау.

**ОТОЩА'ЛЫЙ** *разг.* — ябык, арык.

**ОТОЩА'ТЬ** *сов.* — ябыгу, арыклану.

**ОТПА'ДАТЬ** *сов. разг.* — төшеп бетү, коелып бетү; *к ноябрю листья отпадали* — ноябрьга яфраклар коелып бетте инде.

**ОТПАДА'ТЬ** *несов* — к. отпасть.

**ОТПА'ИВАТЬ I** *несов.* — к. отпоить.

**ОТПА'ИВАТЬ II** *несов.* — к. отпаять.

**ОТПА'ИВАТЬСЯ I** *несов. страд.* — эчертеп терелтелү; *в некоторых случаях отравленные отпаиваются молоком* — кайбер очракларда агуланган кешеләр сөт эчертеп терелтеләләр.

**ОТПА'ИВАТЬСЯ II** *несов.* — 1. к. отпаяться; 2. *страд.* эретеп алыну, эретеп төшерелү.

**ОТПА'ЛЗЫВАТЬ** *несов.* — к. отползать.

**ОТПА'ЛЫВАТЬ** *несов.* — к. отполоть.

**ОТПА'РИВАТЬ** *несов.* — к. отпарить.

**ОТПА'РИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. отпариться; 2. *страд.* парлап йомшартылу, пешекләнү; парлап куптарып алыну.

**ОТПАРИ'РОВАТЬ** *сов. книж.* — 1. кире кагу, кире кайтару (кылыч сугышында); *отпарировать удар* — сугуны кире кайтару; 2. *перен.* кире кагу; *отпарировать возражение* — каршы сүзне кире кагу, каршы әйткәнне кире кагу.

**ОТПА'РИТЬ** *сов.* — 1. *разг.* (*отутюжить через мокрую тряпку*) юеш чүпрәк аша үтүкләп чыгу; 2. парда йомшарту, пешекләп алу; *отпарить репу* — шалканны парда йомшарту; 3. (*отделить, подвергая действию пара*) парлап куптарып алу; 4. (*кончить парить*) чабындырып бетерү, чабындырып туктау.

**ОТПА'РИТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. (*размягчиться под действием пара*) парланып йомшау, пешекләнү; 2. (*отделиться под действием пара*) парда йомшап аерылу, парда йомшап кубу; 3. (*кончить париться в бане*) чабынып бетү, чабынып туктау, чабынудан туктау.

**ОТПА'РЫВАТЬ** *несов.* — к. отпороть.

**ОТПА'РЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. отпороться; 2. *страд.* сүтелү, сүтеп алыну.

**ОТПАСТИ'** *сов.* — 1. (*кончить пастьбу*) көтү, көтеп туктау, (көтү) көтүдән туктау; *отпасти скот* — мал көтүдән туктау; 2. көтүчелектән чыгу, көтүчелекне ташлау.

**ОТПАСТИ'СЬ** *сов. простореч.* — к. отпасти 2.

**ОТПА'СТЬ** *сов.* — 1. (*оторваться, отвалиться*) өзелеп төшү, коелып төшү; 2. ватылып төшү; *ручка чайника отпала* — чәйнекнең тоткасы ватылып төшкән; 3. *книж.* аерылу; төшеп калу, чыгу; *отпасть от семьи* — семьядан аерылу; *отпасть от организации* — оешмадан төшеп калу; 3. югалу, бетү, юкка чыгу; *все его возражения отпали* — аның каршы әйткәннәренең барысы да юкка чыкты; 4. бетү, үтү; *желание отпало* — теләк бетте.

**ОТПАХА'ТЬ** *сов.* — 1. (*закончить пахать*) сөреп бетерү, сукалап бетерү; сөрүдән туктау, сукалаудан туктау; 2. сөреп үткәрү; *отпахать два дня* — ике көн сөреп үткәрү.

**ОТПАХА'ТЬСЯ** *сов. простореч.* — к. отпахать 1.

**ОТПА'ХИВАТЬ** *несов.* — к. отпахнуть.

**ОТПА'ХИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. отпахнуться; 2. *страд.* ачып җибәрелү.

**ОТПАХНУ'ТЬ** *сов. разг.* — ачып җибәрү; *отпахнуть полу* — чабуны ачып җибәрү; *отпахнуть дверцу гардероба* — гардеробның капкачын ачып җибәрү.

**ОТПАХНУ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — ачылып китү; *дверца автомобиля отпахнулась* — автомобильнең ишеге ачылып китте; *пола отпахнулась* — чабу ачылып китте.

**ОТПАЯ'ТЬ** *сов.* — эретеп алу, эретеп төшерү; *отпаять кран у самовара* — самоварның борынын эретеп төшерү.

**ОТПАЯ'ТЬСЯ** *сов.* — эреп төшү; *у самовара отпаялся кран* — самоварның борыны эреп төшкән.

**ОТПЕВА'ТЬ** *несов.* — к. отпеть.

**ОТПЕВА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. җырлап бетерелү, җырлап бирелү; 2. *церк.* җеназа укылу.

**ОТПЕКА'ТЬ** *несов.* — к. отпечь.

**ОТПЕКА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. *простореч.* к. отпечься; 2 *страд.* пешерелеп бетү.

**ОТПЕРЕ'ТЬ** *сов.* — ачу; *отпереть замок* — йозакны ачу.

**ОТПЕРЕ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. ачылу; *ворота отперлись легко* — капка җиңел ачылды; 2. *разг.* тану; *он отпёрся ото всего, что говорил* — ул әйткән сүзләреннән танды.

**ОТПЕ'ТЫЙ** — 1. җырланган; *отпетая песнь* — җырланган җыр; 2. җеназа укылган; *отпетый покойник* — җеназа укылган мәет; 3. *перен.* (*неисправимый, безнадёжный*) төзәлмәслек. ◇ **Отпетый дурак** — шыр тиле.

**ОТПЕ'ТЬ** *сов.* — 1. (*кончить пение*) җырлап туктау, җырлаудан туктау; 2. (*пропеть*) җырлап бирү; 3. *церк.* җеназа уку. ◇ **Петухи отпели** — әтәчләр кычкырды инде.

**ОТПЕЧА'ТАТЬ** *сов.* — 1. басып чыгару; *отпечатать книгу* — китап басып чыгару; 2. *разг.* (*отпереть, раскрыв или уничтожив печать*) печатен ватып ачу, печатен ватып керү; 3. эз калдыру; *отпечатать пальцы на стекле* — пыялада бармак эзләрен калдыру; 4. кырт кисеп әйтү, әйтеп салу, өзеп әйтү; ачык итеп әйтү; *так и отпечатал ему* — шулай итеп кырт кисеп әйтте дә салды.

**ОТПЕЧА'ТАТЬСЯ** *сов.* — эз калу; *копыта лошади отпечатались на дорожке* — юлда ат тоякларының эзе калган.

**ОТПЕЧАТЛЕВА'ТЬ** *несов. книж. устар.* — к. отпечатлеть.

**ОТПЕЧАТЛЕВА'ТЬСЯ** *несов. книж. устар.* — 1. к. отпечатлеться; 2. *страд.* эз калдырылу.

**ОТПЕЧАТЛЕ'ТЬ** *сов.* — эз калдыру.

**ОТПЕЧАТЛЕ'ТЬСЯ** *сов.* — истә калу, күңелгә сеңү, күңелдә калу.

**ОТПЕЧА'ТОК** *м.* — 1. эз; *на книге остались отпечатки пальцев* — китапта бармак эзләре калган; 2. *перен.* тәэсир, йогынты, эз; *отпечаток прежних несчастий* — элекке бәхетсезлекләрнең тәэсире, эзе; 3. *перен.* (*особенность*) үзенчәлек билгесе, үзенчәлек.

**ОТПЕЧА'ТЫВАТЬ** *несов.* — к. отпечатать 2, 3, 4.

**ОТПЕЧА'ТЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. отпечататься; 2. *страд.* эз калдырылу.

**ОТПЕ'ЧЬ** *сов.* — 1. пешереп бетерү; 2. пешеренеп бетү.

**ОТПЕ'ЧЬСЯ** *сов.* — 1. (*выпечься*) пешеп житү; 2. (*окончить работу по печению*) пешеренеп бетү.

**ОТПИВА'ТЬ** *несов.* — к. отпить.

**ОТПИВА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. отпиться; 2. *страд.* аз гына эчеп алыну.

**ОТПИ'ЛИВАТЬ** *несов.* — к. отпилить.

**ОТПИ'ЛИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — (пычкы белән) кисеп алыну, кисеп ташлану.

**ОТПИЛИ'ТЬ** *сов.* — (пычкы белән) кисеп алу, кисеп ташлау.

**ОТПИРА'ТЕЛЬСТВО** *ср. устар.* — тану, хакыйкатьне яшерү, дөресен әйтмәү.

**ОТПИРА'ТЬ** *несов.* — к. отпереть.

**ОТПИРА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. отпереться; 2. *страд.* ачылу; *дверь отпирается* — ишек ачыла.

**ОТПИСА'ТЬ** *сов.* — 1. (*убавить что-н. из написанного*) сызу, киметү (язганнан); 2. *устар.* (*назначить в наследство*) мирас итеп калдыру; 3. *офиц. устар.* конфисковать итеп алу; *имение отписано в казну* — имение казнага конфисковать итеп алынган; 4. *устар.* (*снять с учёта*) учёттан төшерү; 5. (*известить письмом*) хат белән белдерү, язып жибәрү; 6. *разг.* (*закончить писание*) язу эшләрен бетерү, язудан бушау.

**ОТПИСА'ТЬСЯ** *сов.* — 1. язып котылу (формаль җавап җибәреп чикләнү); 2. *простореч.* (*сняться с учёта*) учёттан төшү.

**ОТПИ'СКА** *ж.* — формаль җавап, буш кәгазь; *канцелярская отписка* — канцеляриянең формаль җавабы.

**ОТПИ'СЫВАТЬ** *несов.* — к. отписать.

**ОТПИ'СЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. отписаться; 2. *страд.* мирас итеп бирелү; 3. *страд.* конфисковать ителү; 4. *страд.* учёттан төшерелү.

**ОТПИ'ТЬ** *сов.* — 1. аз гына эчеп алу, аз гына эчеп җибәрү; *отпей воды* — аз гына су эчеп җибәр; 2. эчеп бетерү; *давно отпили чай* — күптән чәй эчеп бетердек.

**ОТПИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — эчеп савыгу, эчеп терелү; *отпиться кумысом* — кымыз эчеп савыгу.

**ОТПИ'ХИВАТЬ** *несов.* — к. отпихнуть.

**ОТПИ'ХИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. отпихнуться; 2. *страд.* эткәләп (төрткәләп) җибәрелү.

**ОТПИХНУ'ТЬ** *сов.* — 1. (*пихая, оттолкнуть от чего-н.*) этеп җибәрү, төртеп җибәрү, этәреп җибәрү; 2. *перен. разг. фам.* (*отстранить, отделаться*) читкә ташлау.

**ОТПИХНУ'ТЬСЯ** *сов.* — этәрелеп китү; *отпихнуться от берега* — ярдан этәрелеп китү.

**ОТПЛАТИ'ТЬ** *сов.* — 1. түләү, җавап кайтару, җавап бирү; *отплатить добром за добро* — яхшылыкка яхшылык белән җавап кайтару; 2. (*отомстить за причинённое зло*) үч алу, үч кайтару. ◇ **Отплатить тою же монетою** — бермә-бер кайтару, ашка аш белән, ташка таш белән.

**ОТПЛА'ЧИВАТЬ** *несов.* — к. отплатить.

**ОТПЛА'ЧИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — түләнү, кайтарылу, җавап бирелү.

**ОТПЛЕВА'ТЬ** *сов. разг. фам* — төкеренүдән туктау.

**ОТПЛЕВА'ТЬСЯ** *сов. разг. фам.* — 1. төкеренеп бетү; 2. *перен. вульг.* (*отделаться, отвязаться*) котылу, арыну.

**ОТПЛЁВЫВАТЬ** *несов.* — 1. к. отплевать; 2. к. отплюнуть.

**ОТПЛЁВЫВАТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. төкеренү; 2. *страд.* төкереп ташлану, төкереп чыгарылу.

**О'ТПЛЕСК** *м.* — чәчрәү (су, сыек әйбер).

**ОТПЛЕСКА'ТЬ** *сов.* — чәчрәтеп туктау, чәчрәтүдән туктау.

**ОТПЛЕСНУ'ТЬ** *сов. разг.* — 1. кире китү, кире чәчрәү; *волна отплеснула, ударившись в берег* — дулкын ярга бәрелеп, кире китте; 2. (*отлить*) түгә төшү, кимегә төшү (суны).

**ОТПЛЕСТИ'** *сов.* — 1. сүтеп алу (үрелгәнне); *отплести ленту* — лентаны сүтеп алу; 2. *разг.* үреп бетерү; *отплести косу* — чәч толымын үреп бетерү; 3. (*кончить плетение*) үрүдән туктау.

**ОТПЛЕСТИ'СЬ** *сов.* — сүтелү; *лента отплелась* — тасма сүтелгән.

**ОТПЛЕТА'ТЬ** *несов.* — к. отплести.

**ОТПЛЕТА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. отплестись; 2. *страд.* сүтеп алыну (үрелгән әйбер турында).

**ОТПЛЫВА'ТЬ** *несов.* — к. отплыть.

**ОТПЛЫ'ТЬ** *сов.* — 1. йөзеп китү; *отплыть на версту от берега* — ярдан бер чакрымга йөзеп китү; 2. *разг.* кузгалып китү, китү; *корабль отплыл ночью* — корабль төнлә китте.

**ОТПЛЮ'НУТЬ** *сов.* — төкереп ташлау.

**ОТПЛЮ'НУТЬСЯ** *сов. разг.* — төкеренеп кую, чирканып төкеренеп кую.

**ОТПЛЯСА'ТЬ** *сов.* — 1. (*проплясать*) биеп алу; 2. (*окончить пляску*) биюдән туктау; 3. бии-бии авырттыру, авырттырып бетерү; *отплясать все ноги* — бии-бии аякларны авырттырып бетерү.

**ОТПЛЯСА'ТЬСЯ** *сов. простореч.* — к. отплясать 2.

**ОТПЛЯ'СЫВАТЬ** *несов.* — 1. к. отпля-

сать; 2. (*танцевать с увлечением*) бирелеп бию.

**О'ТПОВЕДЬ** *ж. книж.* — шелтәле җавап, катгый рәвештә кире кагу, кискен җавап.

**ОТПОИ'ТЬ** *сов.* — 1. эчереп үстерү, эчереп симертү; *отпоить щенка молоком* — эт баласын сөт эчереп үстерү; *отпоить телёнка на убой* — бозауны сөт эчереп сугымга симертү; 2. *разг.* эчереп терелтү, эчереп савыктыру; *отпоить молоком отравленного* — агуланган кешене сөт эчереп терелтү; 3. (*кончить поить*) эчерүдән туктау.

**ОТПОЛА'СКИВАТЬ** *несов.* — к. отполоскать.

**ОТПОЛА'СКИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. отполоскаться; 2. *страд.* чайкап алыну.

**ОТПО'ЛДНИЧАТЬ** *сов. разг.* — төшке ашны ашап бетерү.

**ОТПО'ЛЗАТЬ** *сов. разг.* — шуышудан туктау, шуышып йөрүдән туктау.

**ОТПОЛЗА'ТЬ** *несов.* — к. отползти.

**ОТПОЛЗТИ'** *сов.* — шуышып китү, үрмәләп китү, мүкәләп китү; *ребёнок отполз на четвереньках* — бала дүрт аяклап үрмәләп китте.

**ОТПОЛИРОВА'ТЬ** *сов.* — 1. шомарту, ялтырату, шомартып чыгу, ялтыратып чыгу; 2. лак белән ялтырату.

**ОТПОЛИРО'ВЫВАТЬ** *несов.* — к. отполировать 2.

**ОТПОЛИРО'ВЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — шомартылу, ялтыратылу.

**ОТПОЛОСКА'ТЬ** *сов.* — 1. чайкап юу; *отполоскать бельё добела* — керләрне агартканчы чайкап юу; 2. чайкап бетерү; *отполоскать бельё* — керләрне чайкап бетерү; 3. (*кончить полосканье*) кер чайкаудан туктау.

**ОТПОЛОСКА'ТЬСЯ** *сов.* — 1. чайкалу; *бельё хорошо отполоскалось* — керләр яхшы чайкалган; 2. *простореч.* чайкап бетерү, кер чайкаудан туктау; 3. (*кончить брызгаться*) су чәчрәтүдән туктау.

**ОТПОЛОСОВА'ТЬ** *сов.* — 1. буй-буй итеп телгәләп бетерү (тимерне); 2. *перен. простореч.* (*избить плетью*) чыбыркы белән яру (кыйнау).

**ОТПОЛО'ТЬ** *сов.* — 1. утап бетерү, утап чыгу; 2. утау эшләрен бетерү.

**ОТПО'Р** *м. мн.* нет — отпор, кире кагу, кискен каршылык күрсәтү.

**ОТПОРО'ТЬ** I *сов.* — сүтү, сүтеп алу; *отпороть рукав* — җиңне сүтеп алу.

**ОТПОРО'ТЬ** II *сов. простореч.* — (чыбык, камчы белән) суктыру, чыбыркылау.

**ОТПОРО'ТЬСЯ** *сов.* — сүтелү, сүтелеп төшү.

**ОТПОТЕВА'ТЬ** *несов. разг.* — к. отпотеть.

**ОТПОТЕ'ТЬ** *сов.* — к. запотеть 1.

**ОТПО'ТЧЕВАТЬ** *сов. разг.* — сыйлау, сыйга сый белән җавап кайтару.

**ОТПОЧКОВА'ТЬСЯ** *сов.* — 1. *биол.* (*возникнуть путём почкования*) бөреләнеп аерылу, бөреләнеп аерылып чыгу, тармаклану; 2. *перен.* (*возникнуть, появиться*) барлыкка килү, килеп чыгу (бер бөтеннән).

**ОТПОЧКО'ВЫВАТЬСЯ** *несов.* — к. отпочковаться.

**ОТПРАВИ'ТЕЛЬ** *м.*, **ОТПРАВИ'ТЕЛЬНИЦА** *ж. офиц.* — җибәрүче; *отправитель письма* — хат җибәрүче.

**ОТПРА'ВИТЬ** *сов.* — 1. җибәрү, озату; *отправить товар багажом* — товарны багаж белән җибәрү; *отправить семью в деревню* — семьяны авылга озату; 2. *спец.* китәргә рөхсәт бирү, җибәрү; *отправить поезд* — поездны җибәрү.

**ОТПРА'ВИТЬСЯ** *сов.* — китү; *отправиться гулять* — гулять итәргә китү; *поезд отправится через час* — поезд бер сәгатьтән китә.

**ОТПРАВЛЕ'НИЕ** *ср.* — 1. *только ед.* (*действие*) к. отправить, отправиться; 2. *книж.* эшчәнлек; *это ведёт к понижению умственных отправлений* — бу акылның эшчәнлеген киметүгә алып бара; 3. *офиц.* отправление (җибәрелә торган әйбер, мәсәлән, бандероль, хат, посылка).

**ОТПРАВЛЯ'ТЬ** *несов.* — 1. к. отправить; 2. үтәү, башкару; *отправлять обязанности заведующего* — мөдирлек вазифасын үтәү.

**ОТПРАВЛЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. отправиться; 2. *страд.* җибәрелү, озатылу; 3. *разг. фам.* китү; *отправляйся, куда хочешь* — теләсәң кая кит; 4. *книж.* ...-дан чыгып эш итү, ...-га таянып эш итү; *отправляться от марксизма* — марксизмнан чыгып эш итү; *отправляться от проверенных данных* — тикшерелгән мәгълүматларга таянып эш итү.

**ОТПРАВНО'Й** *книж.* — 1. нигез итеп алынган; *отправной тезис* — нигез итеп алынган тезис; 2. китү ...-ы, озату ...-ы; *отправной пункт* — китү пункты.

**ОТПРА'ВОЧНЫЙ** *разг.* — җибәрү ...-ы; *отправочная контора* — җибәрү конторасы.

**ОТПРА'ЗДНОВАТЬ** *сов.* — 1. бәйрәм итү; 2. (*кончить праздновать*) бәйрәм итеп туктау.

**ОТПРА'ШИВАТЬ** *несов. разг.* — к. отпросить.

**ОТПРА'ШИВАТЬСЯ** *несов.* — к. отпроситься.

**ОТПРЕССОВА'ТЬ** *сов. спец.* — пресслау, пресс белән кыстыру.

**ОТПРОСИ'ТЬ** *сов. разг.* — үтенеп алып калу, үтенеп коткарып алу, үтенеп йолып алу; *отпросить от наказания* — үтенеп җәза бирүдән алып калу.

**ОТПРОСИ'ТЬСЯ** *сов.* — рөхсәт алу (кая булса да китәргә, барырга); *отпроситься в отпуск* — отпускка китәргә рөхсәт алу.

**ОТПРУ'КАТЬ** *сов. простореч.* — атны „тпру" дип туктату.

**ОТПРЫ'ГАТЬ** *сов. разг.* — 1. (*прыгая, удалиться в сторону*) сикереп читкә китү, сикерә-сикерә читкә китү; 2. (*перестать прыгать*) сикерүдән туктау. ◇ **Вы, батюшка, отпрыгали свой век** — сезнең инде, туганкай, сикергәләп йөри торган вакытларыгыз үткән.

**ОТПРЫ'ГИВАТЬ** *несов.* — к. отпрыгнуть, отпрыгать.

**О'ТПРЫ'ГНУТЬ** *сов.* — сикереп китү, ыргып китү, кире сикерү; *мяч отпрыгнул от стены* — туп стенадан кире сикерде.

**О'ТПРЫСК** *м. книж.* — 1. (*молодой побег растения*) үренте, яшь ботак; 2. *устар. ирон.* токым, калдык; *отпрыск княжеского рода* — князь нәселенең калдыгы.

**ОТПРЯГА'ТЬ** *несов.* — к. отпрячь.

**ОТПРЯГА'ТЬСЯ** *несов.* — к. отпрячься.

**ОТПРЯДА'ТЬ** I *несов.* — к. отпрясть.

**ОТПРЯДА'ТЬ** II *несов.* — к. отпрянуть.

**ОТПРЯДА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. *простореч.* к. отпрясться; 2. *страд.* эрләнеп бетү (йон, житен һ. б. турында).

**ОТПРЯ'ДЫВАТЬ** *несов.* — к. отпрянуть.

**ОТПРЯ'НУТЬ** *сов.* — читкә тайпылу, (артка яки читкә таба) сикереп китү; *отпрянуть в ужасе* — куркудан читкә тайпылу.

**ОТПРЯ'СТЬ** *сов.* — 1. (*кончить прясть*) эрләп бетерү; 2. (*пропрясть известное время*) эрләп алу (берникадәр вакыт); 3. (*кончить прядение*) эрләүдән туктау.

**ОТПРЯ'СТЬСЯ** *сов. простореч.*— к. отпрясть 3.

**ОТПРЯ'ЧЬ** *сов.* — тугару.

**ОТПРЯ'ЧЬСЯ** *сов.* — тугарылу; *пристяжная в дороге отпряглась* — юлда мичәү аты тугарылды.

**ОТПУ'ГИВАТЬ** *несов.*— к. отпугнуть.

**ОТПУ'ГИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — куркытып җибәрелү, куркытып куып җибәрелү.

**ОТПУГНУ'ТЬ** *сов.* — 1. куркытып җибәрү, куркытып куып җибәрү; 2. *перен.* куркыту, өркетү; *его отпугнула сложность работы* — аны эшнең катлаулы булуы куркытты.

**О'ТПУСК** *м.* — 1. *только ед.* (*действие*) к. отпустить; 2. отпуск, ял; *получить отпуск* — отпуск алу, ялга чыгу; 3. *канц.* копия (эш кәгазенең копиясе); 4. *тех.* кайтару (корычның уалучанлыгын киметү).

**ОТПУСКА'ТЬ** *несов.* — к. отпустить.

**ОТПУСКА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. отпуститься; 2. *страд.* китәргә рөхсәт бирелү, җибәрелү; чыгарып җибәрелү; бушатылу, бушатыла төшү.

**ОТПУСКНИ'К** *м.* — отпускка чыккан кеше, отпусктагы кеше.

**ОТПУСКНО'Й** — 1. отпуск ...-ы; *отпускное время* — отпуск вакыты; 2. *истор.* (*вольная грамота*) азатлык язуы (азат итү турында бирелгән язу); 3. *экон.* сату ...-ы; *отпускные цены на товары* — товарларның сату бәяләре.

**ОТПУСТИ'ТЬ** *сов.* — 1. (*позволить уйти*) китәргә рөхсәт итү, рөхсәт бирү, җибәрү; 2. чыгару, чыгарып җибәрү (урыныннан); *отпустить дворника* — дворникны урыныннан чыгару; 3. җибәрү, бушайту, бушайта төшү; *отпустить пояс* — билбауны бушайта төшү; 4. сату, җибәрү; *кухня отпустила сто обедов* — кухня йөз обед саткан; 5. *офиц.* ассигновать итү, җибәрү, бирү; *отпустить тысячу рублей на покупку книг* — китаплар сатып алу өчен мең сум акча җибәрү; 6. үстерү, җибәрү; *отпустить бороду* — сакал җибәрү; *отпустить волосы* — чәч үстерү; 7. ычкындыру, әйтеп салу; *отпустить шутку* — шаян сүз ычкындыру; 8. *спец.* үткенләү; *отпустить саблю* — кылычны үткенләү; 9. *тех.* кайтару (корычның уалучанлыгын киметү); 10. *устар.* (*простить долг, грехи, вину*) кичерү (гөнаһны, гаепне һ. б.). ◇ Боль отпустило *безл. разг.* — авырту басылды.

**ОТПУСТИ'ТЬСЯ** *сов. спец.*— йомшау, йомшый төшү, бушау, бушый төшү.

**ОТПУ'ТАТЬ** *сов.*— чишеп алу (чуалганны); *отпутать верёвку* — чуалган бауны чишеп алу.

**ОТПУ'ТАТЬСЯ** *сов. разг.*— 1. чишелү (чуалган җеп, бау турында); *верёвка еле отпуталась* — бау көчкә генә чишелде; 2. (*кончить путаться*) буталмый башлау, чуалудан туктау.

**ОТПУТЕШЕ'СТВОВАТЬ** *сов.* — сәяхәттә йөрүдән туктау, сәяхәт итми башлау, сәяхәт итүдән туктау.

**ОТПУ'ТЫВАТЬ** *несов.*— к. отпутать.

**ОТПУ'ТЫВАТЬСЯ** *несов.*—1 к. отпутаться; 2. *страд.* чишеп алыну.

**ОТПУЩЕ'НИЕ** *ср. книж. торж. устар.*— гөнаһларны кичерү.

**ОТПУ'ЩЕННИК** *м. истор.*— к. вольноотпущенник.

**ОТПЫЛО'ВКА** *ж. мн.* нет, *спец.*— тузаннан чистарту (чималны, ярым фабрикатларны).

**ОТПЫЛО'ВЩИК** *м. спец.*— отпыловщик, тузаннан чистартучы эшче (чималны, ярым фабрикатларны).

**ОТПЫХТЕ'ТЬСЯ** *сов. разг. фам.*— уфылдап туктау, уфылдаудан туктау.

**ОТПЯ'ЛИВАТЬ** *несов. простореч.* — к. отпялить.

**ОТПЯ'ЛИВАТЬСЯ** *несов. простореч.* — 1. к. отпялиться; 2. *страд.* ачылу, аерылу.

**ОТПЯ'ЛИТЬ** *сов. простореч.* — ачу, аеру; *отпялить пальцы* — бармакларны аеру.

**ОТПЯ'ТИТЬ** *сов. простореч.*— чигендерү; *отпятить лошадь* — атны чигендерү.

**ОТПЯ'ТИТЬСЯ** *сов. простореч.*— чигенү.

**ОТПЯ'ЧИВАТЬ** *несов. простореч.* — к. отпятить.

**ОТПЯ'ЧИВАТЬСЯ** *несов. простореч.* — 1. к. отпятиться; 2. *страд.* чигендерелү.

**ОТРАБА'ТЫВАТЬ** *несов.* — к. отработать.

**ОТРАБА'ТЫВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. отработаться; 2. *страд.* эшләп түләнү, эш белән түләнү.

**ОТРАБО'ТАТЬ** *сов.* — 1. (*возместить трудом*) эшләп түләү, эш белән түләү; 2. эшләп чыгу; *отработал восемь часов* — сигез сәгать эшләп чыктым; 3. (*кончить работу*) эшне бетерү, эшләп бетерү, эштән туктау; 4. *спец.* яхшы итеп өйрәнү; *отработать физкультурные упражнения* — физкультура күнегүләрен яхшы итеп өйрәнү.

**ОТРАБО'ТАТЬСЯ** *сов.* — яраксызлану, яраксыз хәлгә килү; *мотор отработался* — мотор яраксызланган, мотор яраксыз

хәлгә килгән. 2. *простореч.* к. отработать 3.

**ОТРАБО'ТКА** *ж.*— 1. *только ед. (действие)* к. отработать; 2. *истор.* отработка, алпавытка эшләү.

**ОТРАБО'ТОЧНЫЙ** — эшләп түләнә торган, эшләп түләү ...-ы; *отработочная система* — эшләп түләү системасы.

**ОТРА'ВА** *ж. разг.*— агу, зәһәр.

**ОТРАВИ'ТЕЛЬ** *м.*, **ОТРАВИ'ТЕЛЬНИЦА** *ж.*— агулаучы.

**ОТРАВИ'ТЕЛЬНЫЙ** *устар.*— агулы, агулый торган; *отравительный напиток*— агулы эчемлек.

**ОТРАВИ'ТЬ** *сов.*— 1. агулау, агулап үтерү; *отравить мышь* — тычканны агулап үтерү; 2. агу кушу, агу салу, агулау; *отравить воду* — суны агулау, суга агу салу; 3. *перен.* агулау (начар йогынты ясау); *отравить сознание религией* — аңны дин белән агулау; 4. *перен. разг.* бозу, ямен китәрү, ләззәтен бетерү; *он отравил весь вечер* — ул бөтен кичнең ямен китәрде.

**ОТРАВИ'ТЬСЯ** *сов.*— агу эчеп үлү, үзенүзе агулап үтерү, агулану.

**ОТРАВЛЯ'ТЬ** *несов.*— к. отравить.

**ОТРАВЛЯ'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. отравиться; 2. *страд.* агуландырылу; бозылу; яме китәрелү, ләззәте бетерелү.

**ОТРА'ВНЫЙ** *устар.*— 1. агулы, агулый торган; 2. *перен.* җирәнгеч, алама, нәҗес.

**ОТРА'ДА** *ж.*— куаныч, шатлык, сөенеч.

**ОТРА'ДНЫЙ** — куанычлы, шатлыклы; *отрадное явление* — шатлыклы күренеш.

**ОТРАЖА'ЕМОСТЬ** *ж. мн.* нет, *физ.* — кайтарылучанлык, чагылучанлык.

**ОТРАЖА'ТЕЛЬ** *м. спец.* — кайтаргыч, отражатель (яктылык нурларын кайтара торган батынкы көзге).

**ОТРАЖА'ТЕЛЬНЫЙ** *физ.*— чагылдыргыч, кайтаргыч; *отражательные приборы* — кайтаргыч приборлар.

**ОТРАЖА'ТЬ** *несов.*— к. отразить.

**ОТРАЖА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. отразиться; 2. *страд.* гәүдәләндерелү, чагылдырылу; кире кагылу, кире кайтарылу, юкка чыгарылу.

**ОТРАЖЕ'НИЕ** *ср.* — 1. *только ед. (действие)* к. отразить; 2. чагылу; *отражение в зеркале* — көзгедә чагылу; 3. чагылыш; *отражение той эпохи* — шул эпоханың чагылышы.

**ОТРАЗИ'ТЕЛЬ** *м. книж.*— кеше фикерләрен чагылдыручы.

**ОТРАЗИ'ТЬ** *сов.*— 1. кире кайтару, кире кагу; *отразить удар* — ударны кире кайтару; 2. юкка чыгару, кире кагу; *отразить доводы оппонента* — оппонентның дәлилләрен кире кагу; 3. *(воспроизвести)* чагылдыру; 4. гәүдәләндерү, чагылдыру, тасвирлау; *правильно отразить эпоху в романе* — романда эпоханы дөрес чагылдыру.

**ОТРАЗИ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. *(дать своё изображение)* чагылу; 2. тәэсир итү, йогынты ясау; *поездка благотворно отразилась на его здоровье* — йөреп кайту аның сәламәтлегенә яхшы тәэсир итте; 3. *перен.* беленү, сизелү, күренү; *на лице ничего не отразилось* — аның йөзендә бернәрсә дә сизелмәде.

**ОТРАПОРТОВА'ТЬ** *сов.* — 1. *офиц.* рапорт бирү; 2. *перен. ирон. (произнести быстро, монотонно)* такылдап кую, тиз генә сөйләп ташлау.

**ОТРАПОРТО'ВЫВАТЬ** *несов.*— к. отрапортовать.

**ОТРАСЛЕВО'Й** — хуҗалыкның бер тармагына караган; *отраслевой вуз* — хуҗалыкның бер тармагына караган вуз.

**О'ТРАСЛЬ** *ж.*— 1. *устар. (отрог горного хребта)* тау тармагы; 2. *устар. (ветвь растения)* үсемлекнең тармагы, үсемлекнең ботагы; 3. *перен. (потомок, потомство)* токым; 4. бүлек, тармак; *отрасль промышленности* — промышленность тармагы.

**ОТРАСТА'ТЬ** *несов.*— к. отрасти.

**ОТРАСТИ'** *сов.*— үсү, үсеп чыгу, үсеп җитү; *борода отросла до пояса* — сакалы биленә кадәр үскән, сакалы биленә җиткән.

**ОТРАСТИ'ТЬ** *сов.*— үстерү, җибәрү; *отрастить ногти* — тырнак үстерү; *отрастить усы* — мыек җибәрү, мыек үстерү.

**ОТРА'ЩИВАТЬ** *несов.*— к. отрастить.

**ОТРА'ЩИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— үстерелү, җибәрелү.

**ОТРЕ'БЬЕ** *ср. мн.* нет — 1. ташландык, эшкә ярамаган нәрсә, калдык-постык; 2. *перен. книж. презрит.* әдәм актыклары, кабахәт кешеләр.

**ОТРЕВЕ'ТЬ** *сов. разг.*— елаудан туктау, акырудан туктау.

**ОТРЕГУЛИ'РОВАТЬ** *сов. спец.*— рәтләү, ипкә китерү, ипләү, юлга салу.

**ОТРЕГУЛИ'РОВАТЬСЯ** *сов. спец.*— рәтләнү, ипкә килү, ипләнү, юлга салыну.

**ОТРЕДАКТИ'РОВАТЬ** *сов.* — редакцияләп чыгу.

**ОТРЕ'З** *м.*— 1. *только ед. (действие)* к. отрезать 1, 2; 2. *спец. (место, по которому резали)* киселгән урын; 3. *торг. (кусок отрезанной ткани)* кисәк, отрез; 4. *спец. (отделённый участок земли)* җир участогы (бүленеп алынган яки бүлеп бирелгән участок).

**ОТРЕ'ЗАННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— элемтә юклык, бәйләнеш булмау; *отрезанность от культурных центров* — культура үзәкләре белән бәйләнеш булмау.

**ОТРЕ'ЗАТЬ** *сов.*— 1. кисү, кисеп алу; 2. *(отделить путём межевания)* җир кисү, кисеп алу; 3. юлны кисү; *отрезать отступление противнику* — дошманның чигенү юлын кисү; 4. *разг. (грубо и коротко ответить)* — кырт кисеп җавап бирү.

**ОТРЕЗА'ТЬ** *несов.*— к. отрéзать.

**ОТРЕ'ЗАТЬСЯ** *сов. разг.*— киселү, кисеп алыну.

**ОТРЕЗА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— 1. киселү, кисеп алыну; 2. юлы киселү; 3. җир киселү.

**ОТРЕЗВЕ'ТЬ** *сов.*— айну, аегу.

**ОТРЕЗВИ'ТЕЛЬНЫЙ** — айныта торган; *отрезвительный ответ* — айныта торган җавап; *отрезвительный напиток* — айныта торган эчемлек.

**ОТРЕЗВИ'ТЬ** *сов.*— айныту, аекландыру.
**ОТРЕЗВИ'ТЬСЯ** *сов.*— айну, аегу.
**ОТРЕЗВЛЯ'ТЬ** *несов.*— к. отрезвить.
**ОТРЕЗВЛЯТ'ЬСЯ** *несов.*— 1. к. отрезвиться; 2. *страд.* аекландырылу, айнытылу.
**ОТРЕЗНО'Й** — 1. киселмәле (кисеп алына торган); *отрезной купон* — киселмәле купон; 2. кисеп алынган; *отрезные земли* — кисеп алынган җирләр (к. отрезок 2).
**ОТРЕ'ЗОК** *м.*— 1. кисәк; 2. *чаще. мн. истор.* кисенте (1861 елда крепостное право бетерелгәч, алпавытлар тарафыннан крестьяннардан тартып алынган җирләр); 3. *книж.* бер өлеш, ара, кисәк; *отрезок пути* — юлның бер өлеше.
**ОТРЕ'ЗЫВАТЬ** *несов.*— к. отреза́ть.
**ОТРЕ'ЗЫВАТЬСЯ** *несов. страд.*— к. отреза́ться.
**ОТРЕКА'ТЬСЯ** *несов.*— к. отречься.
**ОТРЕКОМЕНДОВА'ТЬ** *сов.*— 1. *устар.* (*познакомить при встрече*) таныштыру; 2. тәкъдим итү; *отрекомендовал его, как своего друга* — аны үзенең дусты итеп тәкъдим итте.
**ОТРЕКОМЕНДОВА'ТЬСЯ** *сов. устар.*— исемен әйтү, танышу.
**ОТРЕКОМЕНДО'ВЫВАТЬ** *несов.*— к. отрекомендовать.
**ОТРЕКОМЕНДО'ВЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. отрекомендоваться; 2. *страд.* таныштырылу; тәкъдим ителү.
**ОТРЕМОНТИ'РОВАТЬ** *сов.*— ремонтлау, ремонт ясау, ремонтлап бетерү.
**ОТРЕПА'ТЬ** *сов. разг. редко*— к. обтрепать.
**ОТРЕПА'ТЬСЯ** *сов. разг. редко* — к. обтрепаться.
**ОТРЁПКИ** *ед.* нет — 1. (*остатки от обработки льна*) чүбек, талкыш; 2. *разг. презрит.* (*поношенная одежда, отрепья*) иске-моски, чүпрәк-чапрак, сәләмә киемсалым.
**ОТРЁПЫШ** *м. разг. фам. пренебр.*— йолкыш, сәләмә киемле кеше.
**ОТРЕ'ПЬЕ** *ср. собир.*— иске-моски, чүпрәк-чапрак, сәләмә, тузып беткән кием.
**ОТРЕТИРОВА'ТЬСЯ** *сов. разг.*— 1. *воен. устар.* (*отступить*) чигенү; 2. (*уйти, скрыться*) качып китү, таю, сызу, шылу.
**ОТРЕТИРО'ВЫВАТЬСЯ** *несов. разг.*— к. отретироваться.
**ОТРЕЧЕ'НИЕ** *ср. книж.*— 1. *только ед.* (*действие*) к. отречься; 2. ваз кичү кәгазе (хокуктан, мирастан ваз кичү турында бирелгән рәсми документ).
**ОТРЕ'ЧЬСЯ** *сов. книж.* — тану, баш тарту, ваз кичү.
**ОТРЕША'ТЬ** *несов.*— к. отрешить.
**ОТРЕША'ТЬСЯ** *несов.* — 1. *книж.* к. отрешиться; 2. *страд. устар. офиц.* азат ителү, коткарылу.
**ОТРЕШИ'ТЬ** *сов. устар. офиц.*— чыгару, алу; *отрешить от должности* — хезмәттән чыгару (урыннан алу).
**ОТРЕШИ'ТЬСЯ** *сов. книж.*—1. котылу; 2. ваз кичү.
**ОТРИ'НУТЬ** *сов. книж. ритор.*— кире кагу, кабул итмәү; *отринуть все мольбы*— бөтен ялваруларын кире кагу.
**ОТРИЦА'НИЕ** *ср.*— 1. (*действие*) к. отрицать; 2. кире җавап, тискәре җавап; *отвечать отрицанием* — кире җавап бирү; 3. *филос.* инкарь, капма-каршылыкларның көрәше (иске белән яңа арасындагы, үлеп бара торганнар белән туып килә торганнар арасындагы көрәш, үсеш процессын тәшкил итә торган көрәш); *отрицание отрицания*— инкарьны инкарь итү; 4. *грам.* юклык кисәкчәләре (мәсәлән, рус телендә „не", татар телендә „-ма-мә").
**ОТРИЦА'ТЕЛЬ** *м. книж. устар.*— инкарь итүче, кире кагучы, скептик (бернәрсәгә дә ышанмый торган кеше).
**ОТРИЦА'ТЕЛЬНЫЙ**—1. кире, каршы; *отрицательный ответ* — кире җавап; 2. кире, тискәре; *опыт дал отрицательные результаты* —тәҗрибә кире нәтиҗә бирде; 3. начар, әшәке; *отрицательный отзыв* — начар отзыв; 4. инкарь итүгә корылган; *отрицательный метод* — инкарь итүгә корылган метод. ◇ Отрицательные числа — тискәре саннар. Отрицательный заряд *физ.*— тискәре корылма.
**ОТРИЦА'ТЬ** *несов.* — тану, кире кагу, инкарь итү, юкка чыгару.
**ОТРИЦА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. кире кагылу, инкарь ителү, юкка чыгарылу; 2. *устар.* (*отпираться*) тану.
**ОТРО'Г** *м.*— тау тармагы; *отроги Карпат* — Карпат тавы тармаклары.
**ОТРОДИ'ТЬСЯ** *сов. простореч.* — үсеп нәсел бирү.
**О'ТРОДУ** *нареч. разг.*— туганнан бирле, туган көннән алып, тумыштан; гомеремдә дә; *я отроду этого не слыхал* — минем моны гомеремдә дә ишеткәнем юк.
**ОТРО'ДЬЕ** *ср. собир.*— 1. *с.-х.* (*разновидность какой-н. породы животных*) токымча; 2. *разг. бран.* (*потомство, дети, тип людей*) тумачалар, нәсел-нәсәп, тәр. ◇ Хамово отродье *презрит. бран. устар.*— иблис токымы.
**ОТРОДЯ'СЬ** *нареч. простореч.*— к. отроду.
**ОТРО'ЕК** *м. спец.*— яңа күч (бал кортларына карата).
**ОТРО'ЖИНА** *ж. простореч.*— к. отрог.
**ОТРОИ'ТЬ** *сов. спец.* — ил аеру, күч аеру (бал кортлары турында).
**ОТРОИ'ТЬСЯ** *сов. спец* — 1. ил аеру, күч аеру; *пчёлы отроились* — бал кортлары күч аерганнар; 2. аерылып чыгу; *отроился рой* — күч аерылып чыкты.
**О'ТРОК** *м.*— 1. яшүсмер (ир бала); 2. *истор.* борынгы Россиядә гаскәри, кече дружиначы.
**ОТРОКОВИ'ЦА** *ж. устар. ритор.* —яшүсмер (кыз бала).
**ОТРО'СТОК** *м.* — үренте, үсенте; *хвостовой отросток* — койрык үсентесе.
**О'ТРОЧЕСКИЙ** *книж.* — яшүсмер ...-ы; *отроческие годы* — яшүсмер еллары.
**О'ТРОЧЕСТВО** *ср. мн.* нет, *книж.* — үсмерлек, үсмерлек чоры, яшүсмер чак.
**О'ТРУБ** *м. истор.*— отруб (1906-1917 ел-

ларда кулак хуҗалыкларын күбәйтү максаты белән община җиреннән кисеп алып аерым крестьяннарның хосусый милкенә бирелгән җир участогы).

**ОТРУ'Б** *м. спец.* — агачның киселгән урыны.

**ОТРУБА'ТЬ** *несов.* — к. отрубить.

**ОТРУБА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — кисеп алыну, кисеп төшерелү.

**О'ТРУБИ** *ед.* нет — көрпә, он көрпәсе.

**ОТРУБИ'ТЬ** *сов.* — 1. чабып өзү, кисеп алу, кисеп төшерү; 2. *разг. фам.* (*ответить кратко, резко*) кырт кисеп әйтү.

**ОТРУБНО'Й** I *истор.* — отруб ...-ы; *отрубное хозяйство* — отруб хуҗалыгы.

**ОТРУБНО'Й** II *спец.* — кисем ...-ы, киселгән урын ...-ы; *отрубная толщина* — киселгән урынның калынлыгы.

**О'ТРУБНЫЙ** *с.-х.* — көрпә..., көрпәдән хәзерләнгән; *отрубный корм* — көрпәдән хәзерләнгән мал азыгы.

**ОТРУГА'ТЬ** *сов.* — тиргәп ташлау.

**ОТРУХЛЯ'ВЕТЬ** *сов.* — черү; *нижние брёвна отрухлявели* — аскы бүрәнәләр черегән.

**ОТРЫБА'ЧИТЬ** *сов. разг.* — балык тотудан туктау, балык тотуны ташлау, балык тоту эшләрен тәмамлау.

**ОТРЫ'В** *м. мн.* нет — 1. *спец.* (*действие*) к. оторвать 1; 2. (*линия отрыва*) өзелү урыны, өзелгән урын; 3. аерылу; *отрыв от масс* — массалардан аерылу.

**ОТРЫВА'ТЬ** I *несов.* — к. отрыть.

**ОТРЫВА'ТЬ** II *несов.* — к. оторвать.

**ОТРЫВА'ТЬСЯ** I *несов.* — 1. к. отрыться; 2. *страд.* казып чыгарылу, казып алыну.

**ОТРЫВА'ТЬСЯ** II *несов.* — 1. к. оторваться; 2. *страд.* өзелү, өзеп алыну. ◇ **Не отрываясь** — баш күтәрми; *она работала не отрываясь* — ул баш күтәрми эшли иде.

**ОТРЫ'ВИСТОСТЬ** *ж. мн.* нет — өзек-өзек булу.

**ОТРЫ'ВИСТЫЙ** — өзек-өзек, өзеп-өзеп, бүлеп-бүлеп; *отрывистая речь* — өзеп-өзеп сөйләү.

**ОТРЫВНО'Й** — ертып алына торган; *отрывной календарь* — ертып алына торган календарь.

**ОТРЫ'ВОК** *м.* — өземтә, өзек; *отрывок из романа* — романнан өзек.

**ОТРЫ'ВОЧНЫЙ** — өзек-өзек, ярты-йорты, тулы булмаган; *отрывочные сведения* — тулы булмаган мәгълүматлар.

**ОТРЫГА'ТЬ** I *сов. простореч. фам.* — кикерүдән туктау, кикереп бетерү.

**ОТРЫГА'ТЬ** II *несов.* — к. отрыгнуть.

**ОТРЫ'ГИВАТЬ** *несов.* — к. отрыгнуть.

**ОТРЫ'ГИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. отрыгнуться; 2. *страд.* кикереп чыгарылу.

**ОТРЫГНУ'ТЬ** *сов.* — кикереп чыгару.

**ОТРЫГНУ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. кикереп чыгарылу; 2. *перен. простореч. фам.* тәэсир калдыру, эз калдыру.

**ОТРЫ'ЖКА** *ж.* — 1. *только ед.* кикерү, кикерек (косып, кикереп чыгарылган әйбер); 2. *перен. презрит.* калдык; *пьянство — отрыжка старого быта* — эчүчелек — иске тормышның калдыгы.

**ОТРЫ'СКАТЬ** *сов.* — 1. эзләнеп йөрүдән туктау; 2. *охот.* (*отойти в сторону*) читкә йөгереп китү, читкә ташлану.

**ОТРЫ'СКИВАТЬ** *несов.* — к. отрыскать.

**ОТРЫ'ТЬ** *сов.* — 1. (*откопать*) казып чыгару, казып алу; 2. *перен. разг.* (*разыскать*) эзләп табу; 3. *разг.* (*кончить рытьё*) казудан туктау.

**ОТРЫ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. *разг.* (*обнаружиться при рытье*) казыганда табылу, казыганда килеп чыгу; 2. *разг.* (*роясь, выбраться наружу*) казынып чыгу; 3. *простореч.* казудан туктау, казу эшләрен тәмамлау.

**ОТРЯ'Д** *м.* — отряд, төркем.

**ОТРЯДИ'ТЬ** *сов.* — җибәрү, җибәрергә билгеләү; *отрядить в разведку* — разведкага җибәрү.

**ОТРЯ'ДНЫЙ** *воен.* — отряд ...-ы; *отрядное имущество* — отряд милке.

**ОТРЯЖА'ТЬ** *несов.* — к. отрядить.

**ОТРЯЖА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — җибәрелү.

**ОТРЯСА'ТЬ** *несов.* — к. отрясти.

**ОТРЯСТИ'** *сов. устар. книж.* — к. отряхнуть. ◇ **Отречемся от старого мира, отрясём его прах с наших ног** — ташлыйк, туганнар, иске дөньяны, китсен аяктан аның тузаны.

**ОТРЯХА'ТЬ** *несов. устар. простореч.* — к. отряхивать.

**ОТРЯХА'ТЬСЯ** *несов. устар. простореч.* — к. отряхиваться.

**ОТРЯ'ХИВАТЬ** *несов.* — к. отряхнуть.

**ОТРЯ'ХИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. отряхнуться; 2. *страд.* селкеп төшерелү, кагып төшерелү.

**ОТРЯХНУ'ТЬ** *сов.* — селкеп төшерү, кагып төшерү; *отряхнуть снег с валенок* — киез итектән карны кагып төшерү.

**ОТРЯХНУ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. кагыну, кагынып алу; 2. котылу; *отряхнуться от лени* — ялкаулыктан котылу.

**ОТСАДИ'ТЬ** *сов.* — 1. аерып утырту; *отсадить молодые кусты малины* — кура җиләгенең яшь куакларын аерып утырту; 2. *простореч. неодобр.* чабып өзү, каерып кисеп алу; *отсадить полхлеба* — ярты икмәкне каерып кисеп алу; *отсадить палец топором* — бармакны балта белән чабып өзү.

**ОТСА'ДОК** *м. сад.* — аерып утыртылган үсемлек.

**ОТСА'ЖИВАТЬ** *несов.* — к. отсадить.

**ОТСА'ЖИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. отсесть; 2. *страд.* аерып утыртылу.

**ОТСАЛЮТОВА'ТЬ** *сов.* — салют бирү.

**ОТСА'СЫВАТЬ** *несов.* — к. отсосать.

**ОТСА'СЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — имеп алыну, суырып алыну.

**ОТСВЕРКА'ТЬ** *сов.* — ялтырамый башлау, ялтыраудан туктау, җемелдәми башлау, җемелдәүдән туктау, сүнү; *звёзды отсверкали* — йолдызлар ялтырамый башладылар.

**О'ТСВЕ'Т** *м.* — яктылык чагылышы, чагылган яктылык.

**ОТСВЕ'ЧИВАТЬ** *несов.* — 1. яктылык ча-

гылдыру, ялтырап тору; 2. *просторечю. фам.* карангылап тору; *уйди отсюда, не отсвечивай!* — кит моннан, караңгылап торма!

**ОТСЕБЯ'ТИНА** *ж. разг.*—1. урынсызга үзеннән өстәү, урынсызга үз сүзләрен кушу, уйдырма; 2. *фам.* үз белдеге белән эшләнгән мәгънәсез эш (яки әйтелгән фикер).

**ОТСЕ'В** *м.* — 1. *только ед.* (*действие*) к. отсеять 1, 2; 2. (*то, что отсеяно*) иләк асты. ◇ Отсев учащихся — укучыларның укуны ташлавы (төрле сәбәптән).

**ОТСЕВА'ТЬ** *несов.*— к. отсеять.

**ОТСЕВА'ТЬСЯ** *несов.*—1. к. отсеяться 1, 3; 2. *страд.* иләп арчылу; иләп бетерелү.

**ОТСЕ'ВКИ** *ед.* нет, *с.-х.*— иләк асты.

**ОТСЕВНО'Й** *спец.* — иләнгән; *отсевная мука* — иләнгән он.

**ОТСЕДА'ТЬ** *несов. спец.*—1. иңү, утыру; *скалы отседают* — кыялар утыра, иңә; 2. кубып төшү; *штукатурка отседает* — штукатурка кубып төшә; 3. *охот.* (*делать прыжок в сторону*) читкә сикерү.

**ОТСЕ'ИВАТЬ** *несов.*— к. отсеять.

**ОТСЕ'ИВАТЬСЯ** *несов.*—1. к. отсеяться; 2. *страд.* иләнү, иләп аерылу; иләктән үткәрелү; сайлап чыгарып ташлану; чәчү эшләре бетерелү.

**ОТСЕ'К** *м. спец.*—1. *устар. обл.* (*чурбан*) бүкән; 2. *спец.* отсек, бүлек; *газовый отсек в дирижаблях* — дирижабльләрнең газ тутырыла торган бүлеге; 3. *воен.* отсек, өзеклек (фронтта гаскәрләр арасында калган урын).

**ОТСЕКА'ТЬ** *несов.*— к. отсечь.

**ОТСЕКА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— кисеп алыну, чабып өзелү, чабып төшерелү; алып ташлану.

**ОТСЕ'ЛЕ** *нареч. устар.*— моннан, биредән.

**ОТСЕЛИ'ТЬ** *сов.*— чыгару, күчерү, күчереп утырту (башка урынга).

**ОТСЕЛИ'ТЬСЯ** *сов.*— күчү, күчеп утыру (башка урынга).

**ОТСЁЛОК** *м. обл.*— күчеп утырган авыл.

**ОТСЕ'ЛЬ** *нареч. устар.*— к. отселе.

**ОТСЕЛЯ'ТЬ** *несов.*— к. отселить.

**ОТСЕЛЯ'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. отселиться; 2. *страд.* күчерелү, күчереп утыртылу.

**ОТСЕ'СТЬ** *сов.*— күчеп утыру.

**ОТСЕЧЕ'НИЕ** *ср. мн.*нет, *книж.*—к. отсечь. ◇ Голову даю на отсечение — башымны кисәргә бирәм.

**ОТСЕ'ЧЬ** *сов.*—1. чабып төшерү, кисеп өзү, чабып өзү; *отсечь сухую ветку* — корыган ботакны чабып өзү; 2. *перен. книж.* (*устранить, удалить*) алып ташлау, бетерү.

**ОТСЕ'ЯТЬ** *сов.*—1. (*отделить, просеивая*) иләү, иләп аеру; 2. *перен.* иләктән үткәрү, сайлап чыгарып ташлау, сайлап чыгару (мәсәлән, укытучылар арасыннан квалификациясезләрен чыгару); 3. чәчеп бетерү; *отсеять ячмень* — арпаны чәчеп бетерү; 4. (*закончить сев*) чәчү эшләрен бетерү, чәчү эшләрен тәмамлау.

**ОТСЕ'ЯТЬСЯ** *сов.*—1. (*просеиваясь, отделиться*) иләнү, иләнеп аерылу, чистару; 2. *перен.* чыгып китү, ташлау, төшеп калу; *за год отсеялось по разным причинам 0,5% учащихся* — бер ел эчендә укучыларның 0,5%ы төрле сәбәпләр аркасында укуларын ташлаган; 3. к. отсеять 4.

**ОТСИДЕ'ТЬ** *сов.*—1. утырып оету; *отсидеть ногу* — утырып аякны оету; 2. *разг.* утырып үткәрү; *отсидеть служебные часы* — эш сәгатьләрен утырып үткәрү; 3. *просторечю.* төрмәдә утырып чыгу; *отсидел два года* — ике ел төрмәдә утырып чыкты.

**ОТСИДЕ'ТЬСЯ** *сов. разг.*—1. качып утырып калу, качып утырып котылу; 2. *перен. презрит.* көрәштән качу, эштән качу (көрәш кызган чакта читтә торып, үзен саклап калу); 3. *просторечю.* ою; *отсиделась нога* — аяк оеды.

**ОТСИ'ЖИВАТЬ** *несов.*— к. отсидеть.

**ОТСИ'ЖИВАТЬСЯ** *несов.*— к. отсидеться.

**ОТСКА'БЛИВАТЬ** *несов.*— кырып алу, кырып төшерү.

**ОТСКА'БЛИВАТЬСЯ** *несов*—1. к. отскоблиться; 2. *страд.* кырып алыну, кырып төшерелү.

**ОТСКАКА'ТЬ** *сов. разг.*—1. (*проехать, отъехать вскачь*) чаптырып үтеп китү, чаптырып читкә китү; 2. (*кончить скакать*) чабудан туктау.

**ОТСКА'КИВАТЬ** *несов.*— к. отскочить.

**ОТСКОБЛИ'ТЬ** *сов.*— к. отскабливать.

**ОТСКОБЛИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — кубып төшү (кырганда).

**ОТСКОЧИ'ТЬ** *сов. разг.*—1.(*отпрыгнуть*) читкә сикерү, сикереп читкә китү; 2. *разг.* өзелеп төшү; *пуговица отскочила* — төймә өзелеп төшкән; 3. *разг. фам.* йогынты ясамау, тәэсир итмәү, тәэсир итә алмау; *все доводы от него отскочили* — бер генә дәлил дә аңа тәэсир итә алмады.

**ОТСКРЕБА'ТЬ** *несов.*— к. отскрести.

**ОТСКРЕБА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— кырып төшерелү, кырып алыну.

**ОТСКРЕСТИ'** *сов. разг.*— кырып төшерү, кырып алу.

**ОТСЛА'ИВАТЬ** *несов.*— к. отслоить.

**ОТСЛА'ИВАТЬСЯ** *несов.*—1. к. отслоиться; 2. *страд.* катлау-катлау итеп кубарып төшерелү.

**ОТСЛОЕ'НИЕ** *ср.*—1. *только ед.* (*действие*) к. отслоить, отслоиться; 2. (*осевший слой*) төпкә утырган катлау.

**ОТСЛОИ'ТЬ** *сов.*— катлау-катлау итеп кубарып алу.

**ОТСЛОИ'ТЬСЯ** *сов.*—1. (*осесть пластами*) төпкә утыру (катлау-катлау булып); 2. *перен. книж.* барлыкка килү; *отслоились новые кадры интеллигенции* — интеллигенциянең яңа кадрлары барлыкка килде.

**ОТСЛОНИ'ТЬ** *сов. разг.*— сөяп куелган әйберне алып кую.

**ОТСЛОНИ'ТЬСЯ** *сов. разг. фам.*— сөялгән җирдән китү.

**ОТСЛОНЯ'ТЬ** *несов. разг.* — к. отслонить.

**ОТСЛОНЯ'ТЬСЯ I** *несов. разг.*—1. к. отслониться; 2. *страд.* сөяп куелган җиреннән алып куелу.

**ОТСЛОНЯ'ТЬСЯ** II *сов. разг. фам. шутл.* — эшсез йөрүдән туктау.

**ОТСЛУ'ЖИВАТЬ** *несов.* — к. отслужить.

**ОТСЛУ'ЖИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — хезмәт срогы тутырылу.

**ОТСЛУЖИ'ТЬ** *сов.* — 1. хезмәт итү, эшләү (инде тәмам булган, эшләнгән эш турында); *отслужил в сторожах три года* — өч ел сторож булып эшләдем; 2. хәрби хезмәт срогын тутырып кайту; 3. *(о предмете)* искерү, эшкә яраксыз хәлгә килү; *(о скоте)* картаю; 4. *церк.* гыйбадәт кылып бетерү; *отслужить молебен* — гыйбадәт кылып бетерү.

**ОТСЛУЖИ'ТЬСЯ** *сов. простореч.* — к. отслужить 2.

**ОТСЛУ'ШАТЬ** *сов. разг.* — тыңлап бетерү, ахырга хәтле тыңлау; *отслушать концерт* — концертны тыңлап бетерү.

**ОТСЛУ'ШИВАТЬ** *несов. разг.* — к. отслушать.

**ОТСЛЮ'НИВАТЬ** *несов. разг. фам.* — к. отслюнить.

**ОТСЛЮНИ'ТЬ** *сов. разг. фам.* — бармак төкереклэп санау.

**ОТСМА'РКИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — к. отсморкаться.

**ОТСМОРКА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. сеңгерү, сеңгереп ташлау; 2. *(кончить сморкаться)* сеңгереп бетерү, сеңгерүдән туктау.

**ОТСМОРКНУ'ТЬСЯ** *сов. однокр. разг.* — к. отсморкаться.

**ОТСОВЕ'ТОВАТЬ** *сов.* — күндерү, (берәр эшне) эшләмәскә киңәш бирү.

**ОТСОРТИРОВА'ТЬ** *сов.* — сортларга аеру, сортларга аерып кую, сайлап аеру; сортировать итү; *отсортировать семена* — орлыкларны сортларга аеру.

**ОТСОРТИРО'ВЫВАТЬ** *несов.* — к. отсортировать.

**ОТСОРТИРО'ВЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — сортларга аерылу, сортировать ителү, сортларга бүленү.

**ОТСОСА'ТЬ** *сов.* — 1. имеп алу; 2. *(кончить сосать)* имеп бетерү, имүдән туктау; 3. *(перестать быть сосунком)* имчәктән аерылу, имүдән туктау; 4. *разг. (повредить сосанием)* имә-имә бозу.

**ОТСО'СНЫЙ** *спец.* — суыргыч, суырып ала торган; *отсосная трубка* — суырып ала торган көпшә.

**ОТСО'ХНУТЬ** *сов.* — 1. корып төшү, корып бетү; *ветка отсохла* — ботак корып төшкән; 2. *простореч.* кору; *рука отсохла* — кул корыган. ◇ **Отсохни язык** *простореч.* — телем корысын; *отсохни язык, если я вру* — әгәр дә алдасам, телем корысын.

**ОТСРО'ЧИВАТЬ** *несов.* — к. отсрочить.

**ОТСРО'ЧИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — срогы кичектерелү; срогы озайтылу.

**ОТСРО'ЧИТЬ** *сов.* — 1. кичектерү; *отсрочить уплату долга на два месяца* — бурычны түләү срогын ике айга кичектерү; 2. *разг.* срогын озайту; *отсрочить удостоверение* — таныклыкның срогын озайту.

**ОТСРО'ЧКА** *ж.* — 1. *(действие)* к. отсрочить; 2. отсрочка; *получить отсрочку по болезни* — авыру сәбәпле отсрочка алу.

**ОТСТАВА'НИЕ** *ср. мн.* нет — 1. *(действие)* к. отстать; 2. артта калганлык, артта калу.

**ОТСТАВА'ТЬ** *несов.* — к. отстать.

**ОТСТА'ВИТЬ** *сов.* — 1. читкә этәреп кую; *отставить стол от окна* — өстәлне тәрәзә янынннан читкә этәреп кую; 2. *офиц. устар.* (*уволить в отставку*) отставкага чыгару; 3. *разг. фам.* (*выгнать, уволить*) хезмәттән чыгару; 4. үзгәртү, көчен бетерү; юкка чыгару; *это распоряжение уже отставили* — ул боерыкны юкка чыгарганнар инде. ◇ **Отставить!** *воен.* — отставить (бирелгән команданы үтәмәскә дигән сүз).

**ОТСТА'ВКА** *ж. мн.* нет — отставка (бөтенләйгә хезмәттән чыгу); *выйти в отставку* — отставкага чыгу.

**ОТСТАВЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. отставить 1, 2, 3.

**ОТСТАВЛЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. читкә алып куелу; 2. отставкага чыгарылу; 3. юкка чыгарылу.

**ОТСТАВНО'Й** — 1. отставкага чыккан; *отставной полковник* — отставкага чыккан полковник; 2. алынмалы, алып куела торган; *отставная рама* — алып куела торган рам, алына торган рам.

**ОТСТА'ИВАТЬ** *несов.* — к. отстоять.

**ОТСТА'ИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. отстояться; 2. *страд.* саклап алып калыну, яклану.

**ОТСТА'ЛОСТЬ** *ж. мн.* нет — артта калганлык.

**ОТСТА'ЛЫЙ** — 1. *в знач. сущ.* артта калучы; *подгонять отсталых* — артта калучыларны ашыктыру; 2. *перен.* артта калган; *отсталый ученик* — укуда артта калган укучы; *отсталые страны* — артта калган илләр.

**ОТСТА'ТЬ** *сов.* — 1. артта калу; аерылып калу; *бык отстал от стада* — үгез көтүдән аерылып калган; *этот ученик очень отстал* — бу укучы бик артта калган; 2. калу; *отстать от поезда* — поезддан калу; 3. аерылу, аралашмый башлау; *отстать от старых друзей* — иске дуслардан аерылу; 4. ташлау; *отстать от курения* — тәмәке тартуны ташлау; 5. *разг.* кубу, кубып төшү; *штукатурка отстала* — штукатурка купкан; 6. *разг.* бәйләнми башлау, бәйләнүдән туктау; *отстаньте от меня* — бәйләнмәгез миңа.

**ОТСТЕГА'ТЬ** *сов.* — 1. (*избить, стегая*) чыбыклау, суктыру; 2. *редко* сырып бетерү, сырып чыгу; *отстегать одеяло* — юрган сырып бетерү.

**ОТСТЁГИВАТЬ** *несов.* — к. отстегнуть.

**ОТСТЁГИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. отстегнуться; 2. *страд.* ычкындырылу; 3. ычкындырып алыну; *воротник у шубы отстёгивается* — туныңң якасы ычкындырып алына.

**ОТСТЕГНУ'ТЬ** *сов.* — чишү, ычкындыру; ычкындырып җибәрү; *отстегнуть воротник* — яканы ычкындыру.

**ОТСТЕГНУ'ТЬСЯ** *сов.* — ычкыну; *пуговицы отстегнулись* — төймәләр ычкынды.

**ОТСТЕЖНО'Й** *разг.*— ычкындырып алына торган, алынмалы; *отстежной воротник* — ычкындырып алына торган яка.

**ОТСТИРА'ТЬ** *сов.*—1. (*отмыть стиркой*) юып бетерү, юып китәрү (тапны); 2. кер юып бетерү.

**ОТСТИРА'ТЬСЯ** *сов.* — юып бетерелү; *пятно отстиралось* — тап юып бетерелде.

**ОТСТИ'РЫВАТЬ** *несов.*— к. отстирать.

**ОТСТИ'РЫВАТЬСЯ** *несов.* —1. к. отстираться; 2. *страд.* юылу, юылып бетү, юып бетерелү.

**ОТСТО'Й** *м. мн.* нет — утырма, турта.

**ОТСТО'ЙНИК** *м. тех.*— тондыру бассейны, тондыру өчен савыт (болганчык суны тондырып чистарту өчен ясалган күл яки савыт).

**ОТСТО'ЙНЫЙ** *тех.*— тондыру ...-ы, тондыра торган; *отстойный колодец* — тондыра торган кое.

**ОТСТОЯ'ТЬ** I *сов.*—1. саклап алып калу; *отстоять крепость* — крепостьны саклап алып калу; 2. яклау, яклап калу; *отстоять свои права* — үз хокукларыны яклап калу; 3. *разг.* басып тору, басып уздыру; *отстоять на ногах весь спектакль* — спектакль беткәнче басып тору; 4. *разг.* басып торып талдырып бетерү; *отстоять ноги* — басып торып аякларны талдырып бетерү.

**ОТСТОЯ'ТЬ** II *несов.*— арырак тору, читтәрәк тору; *дом отстоит от деревни на полкилометра* — йорт авылдан ярты километрга читтәрәк тора.

**ОТСТОЯ'ТЬСЯ** *сов.*—1. (*о жидкости*) тону; *вода отстоялась* — су тонган; 2. *перен.* ныгу, ныгып җитү; *взгляды на жизнь отстоялись* — тормышка карашлар ныгып җитте.

**ОТСТРА'ГИВАТЬ** *несов.*— к. отстрогать.

**ОТСТРА'ГИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — ышкылап алыну, ышкылап төшерелү.

**ОТСТРАДА'ТЬ** *сов.*— газап чигүдән туктау, күп җәфалар күрү, күп җәфалар чигү.

**ОТСТРА'ИВАТЬ** *несов.*— к. отстроить.

**ОТСТРА'ИВАТЬСЯ** *несов.*—1. к. отстроиться; 2. *страд.* төзелеп бетү.

**ОТСТРАНИ'ТЬ** *сов.*—1. этәрү, читкәрәк этү, этәреп җибәрү; *отстранить рукой ветку* — ботакны кул белән этәреп җибәрү; 2. *перен.* читкә китү, читкә ташлау; *отстранить от себя все заботы* — барлык мәшәкатьләрдән читкә китү; 3. *офиц.* чыгару, алу; *отстранить от работы* — эштән алу, эшеннән чыгару.

**ОТСТРАНИ'ТЬСЯ** *сов.*—1. читкә китү, читкә тайпылу; *отстраниться от удара* — сугудан читкә тайпылу; 2. *перен.* бушану, котылу, ташлау; *отстраниться от заведования* — мөдирлекне ташлау.

**ОТСТРАНЯ'ТЬ** *несов.*— к. отстранить.

**ОТСТРАНЯ'ТЬСЯ** *несов.*—1. к. отстраниться; 2. *страд.* этәреп җибәрелү; читкә ташлану; чыгарылу (эштән).

**ОТСТРЕ'ЛИВАТЬ** I *несов.*— к. отстрелить.

**ОТСТРЕ'ЛИВАТЬ** II *несов.*— к. отстрелять.

**ОТСТРЕ'ЛИВАТЬСЯ** *несов.*— к. отстреляться.

**ОТСТРЕЛИ'ТЬ** *сов. разг.*— атып өздерү (пуля яки снаряд белән); *ему отстрелили палец* — аның бармагын атып өздергәннәр.

**ОТСТРЕ'ЛЬЩИК** *м. спец.* — сунарчы, аучы.

**ОТСТРЕЛЯ'ТЬ** *сов.*—1. *спец. охот.* (*охотясь, убить*) аулап атып үтерү; 2. (*окончить стрельбу*) атудан туктау, атып бетерү.

**ОТСТРЕЛЯ'ТЬСЯ** *сов.*— атышып котылу, каршы атып котылу.

**ОТСТРИГА'ТЬ** *несов.*— к. отстричь.

**ОТСТРИГА'ТЬСЯ** *несов.*—1. к. отстричься; 2. *страд.* кыркып ташлану, кисеп ташлану.

**ОТСТРИГНУ'ТЬ** *сов. однокр. простореч.*— к. остричь.

**ОТСТРИ'ЧЬ** *сов.*— кыркып ташлау (чәч турында), кисеп ташлау (тырнак турында).

**ОТСТРИ'ЧЬСЯ** *сов.*—1. кисеп ташлану; *сучок отстригся* — ботак кисеп ташланды; 2. *разг.* чәч алдыру; *я уже отстригся* — мин чәчемне алдырдым инде.

**ОТСТРОГА'ТЬ** *сов.* — 1. стругдап алу, ышкылап алу; ышкылап төшерү; *отстрогай ещё на вершок* — тагын бер вершок ышкылап төшер; 2. к. выстрогать; 3. ышкылап бетерү; *плотники отстрогали и ушли* — балта осталары ышкылап бетерделәр дә киттеләр.

**ОТСТРО'ИТЬ** *сов.*— 1. (*закончить постройку*) төзеп бетерү, корып бетерү, салып бетерү; 2. (*перестроить наново*) яңадан төзү, яңадан салу; 3. җайлау, җайлап кую, көйләү, көйләп кую; *отстроить радиоприёмник* — радиоалгычны көйләп кую.

**ОТСТРО'ИТЬСЯ** *сов.*—1. *разг.* төзеп бетерү, салып бетерү; 2. *спец.* җайлану, көйләнү; *радиоприёмник отстроился* — радиоалгыч җайланды.

**ОТСТРОЧИ'ТЬ** *сов. спец.*—1. каеп чыгу; 2. каюдан туктау.

**ОТСТРУГА'ТЬ** *сов. обл.*— к. отстрогать.

**ОТСТРУ'ГИВАТЬ** *несов. обл.*—к. отстругать.

**ОТСТРУ'ГИВАТЬСЯ** *несов. страд. обл.*— ышкылап алыну, струклап алыну.

**ОТСТРЯ'ПАТЬ** *сов. разг.*—1. (*кончить стряпать*) пешереп бетерү; 2. (*кончить стряпню*) пешеренүдән туктау.

**ОТСТРЯ'ПАТЬСЯ** *сов. простореч.* — к. отстряпать 2.

**ОТСТУ'КАТЬ** *сов. разг.*—1. (*сыграть, воспроизвести, стукая по чему-н.*) шакылдатып көй чыгару; 2. (*напечатать на пишущей машинке*) машинкада басып ташлау; 3. *шутл.* вату, ватып төшерү; *отстукать ручку у двери* — ишекнең тоткасын ватып төшерү.

**ОТСТУ'КИВАТЬ** *несов. разг.*— к. отстукать.

**О'ТСТУП** *м.*—ара, аралык, буш урын (текстны башлап китәр алдыннан буш калдырылган урын).

**ОТСТУПА'ТЕЛЬНЫЙ** — чигенү ...-ы,

артка китү ...-ы; *отступательные операции* — чигенү операцияләре (сугышта).

**ОТСТУПА'ТЬ** *несов.*— к. отступить.

**ОТСТУПА'ТЬСЯ** *несов. разг.*— к. отступиться.

**ОТСТУПИ'ТЬ** *сов.*—1. чигенү, чигү; *отступить на противоположный берег* — елганың икенче ягына чигенү; 2. кире кайту, түнү; *я не отступлю от своих требований* — мин үземнең таләпләремнән кире кайтмам; 3. бозу, каршы бару; *отступить от правила* — кагыйдәне бозу; 4. читкә китү, читкә чыгу; *отступить от темы* — темадан читкә чыгу; 5. (*начать писать не с самого края*) читтән урын калдырып яза башлау.

**ОТСТУПИ'ТЬСЯ** *сов. разг.*—1. баш тарту, артыннан йөрмәү; *приятель его советовал ему жаловаться; но смотритель подумал, махнул рукой и решил отступиться* (Пушкин) — дусты ана жалоба бирергә киңәш иткән иде; ләкин смотритель уйланып торды да, кулын селтәде һәм бу эшнең артыннан йөрмәскә карар бирде; 2. (*порвать связь, отношение с кем-н.*) бәйләнешне өзү, араны өзү.

**ОТСТУПЛЕ'НИЕ** *ср.*—1. (*действие*) к. отступить; 2. (*уклонение, отказ*) баш тарту; 3. чигенеш; *лирическое отступление*— лирик чигенеш; 4. *книж.* читкә китү, тайпылу; *отступление от правила* — кагыйдәдән читкә китү.

**ОТСТУ'ПНИК** *м*, **ОТСТУПНИЦА** *ж. книж. ритор. неодобр.* — мөртәт, хыянәтче.

**ОТСТУ'ПНИЧЕСТВО** *ср. мн.* нет, *неодобр.* — мөртәтлек.

**ОТСТУПНО'Й** *устар.* — ваз кичкән өчен бирелә торган (берәр нәрсәдән, берәр хокуктан); *отступные деньги* — ваз кичкән өчен бирелә торган акча.

**ОТСТУПЯ'** *деепр. устар.*— бераз урын калдырып, ара калдырып; *начать писать, отступя немного от края страницы* — дәфтәр битенең читеннән бераз урын калдырып яза башлау.

**ОТСТУЧА'ТЬ** *сов.*— 1. шакылдаудан туктау, шакылдатып туктау; 2. *разг.* к. отстукать 3.

**ОТСУДИ'ТЬ** *сов. простореч.*— судлашып алу, суд белән кайтарып алу.

**ОТСУДИ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— судлашудан туктау.

**ОТСУ'ЖИВАТЬ** *несов. простореч.*— к. отсудить.

**ОТСУ'ЖИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. *разг.* к. отсудиться; 2. *страд. простореч.* судлашып алыну, суд белән кайтарып алыну.

**ОТСУ'ТСТВИЕ** *ср. мн.* нет — юклык, булмау; *отсутствие сведений* — хәбәрләрнең юклыгы; *твоё отсутствие меня убьёт* — синең булмавың мине харап итәр. ◇ **В отсутствие** — юк чакта; *в моё отсутствие* — мин юк чакта. **Отсутствие всякого присутствия** *разг. шутл.*— юләр, акыл керәп тә чыкмаган, акыл өләшкәндә идән астында калган.

**ОТСУ'ТСТВОВАТЬ** *несов.*— булмау, килмәү; *отсутствовать на занятиях по болезни* — авыру сәбәпле занятиеләрдә булмау; *лёгкие у рыб отсутствуют* — балыкларның үпкәсе булмый (балыкларның үпкәсе юк).

**ОТСУТЯ'ЖИТЬ** *сов. простореч. неодобр. устар.*— дәгъвалашып алу, дәгъвалашып кайтарып алу.

**ОТСУТЯ'ЖНИЧАТЬ** *сов. простореч. неодобр. устар.*— к. отсутяжить.

**ОТСУ'ЧИВАТЬ** *несов.*— к. отсучить.

**ОТСУ'ЧИВАТЬСЯ** *несов.*— 1. *разг.* к. отсучиться; 2. *страд.* төшерелү (җиң, балак турында).

**ОТСУЧИ'ТЬ** *сов.*— 1. *разг.* сызганганны төшерү; *отсучить рукав* — сызганган җиңне төшерү; 2. (*кончить сучение*) катып бетерү (җепне).

**ОТСУЧИ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— төшү (сызганган җиң, балак турында); *рукав отсучился* — җиң төшкән.

**ОТСЧИТА'ТЬ** *сов.*— 1. санап алу, санап чыгу; 2. санап аерып кую.

**ОТСЧИ'ТЫВАТЬ** *несов.*— к. отсчитать.

**ОТСЧИ'ТЫВАТЬСЯ** *несов. страд.*— 1. санап алыну; санап чыгылу; 2. санап аерып куелу.

**ОТСЫЛА'ТЬ** *несов.*— к. отослать.

**ОТСЫЛА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— җибәрелү.

**ОТСЫ'ЛОЧНЫЙ** — җибәрә торган; *отсылочный пункт* — җибәрә торган пункт.

**ОТСЫ'ПАТЬ** *сов.* — бер өлешен бушатып алу, бераз бушату (он, ярма һ. б. турында). ◇ **Отсыпал ему кучу денег** — аңа бик күп акча бирде. **Отсыпать горячих** *простореч. шутл.*— суктыру, кыйнау.

**ОТСЫПА'ТЬ** I *несов.*— к. отсыпать.

**ОТСЫПА'ТЬ** II *несов. разг.*— к. отоспать.

**ОТСЫ'ПАТЬСЯ** *сов. разг.*— сибелү, түгелү, чәчелү.

**ОТСЫПА'ТЬСЯ** I *несов.*— 1. *разг.* к. отсыпаться; 2. *страд.* бераз бушатылу, бушатып алыну.

**ОТСЫПА'ТЬСЯ** II *несов.*— к. отоспаться.

**ОТСЫПНО'Й** *простореч.* — бушатып алынган; *отсыпная мука* — бушатып алынган он.

**ОТСЫРЕВА'ТЬ** *несов.*— к. отсыреть.

**ОТСЫРЕ'ЛЫЙ** — юешләнгән, дымланган; *отсырелый табак* — дымланган тәмәке.

**ОТСЫРЕ'ТЬ** *сов.*— юешләнү, дымлану; *порох отсырел* — дары дымланган.

**ОТСЫХА'ТЬ** *несов.*— к. отсохнуть.

**ОТСЮ'ДА** *нареч.* — 1. моннан, шушы урыннан; *отсюда до реки один километр* — моннан елгага кадәр бер километр; 2. *перен. книж.* шул сәбәптән, шуның аркасында, моннан; *отсюда можно заключить следующее* — моннан түбәндәге нәтиҗәгә килергә мөмкин.

**ОТТА'ИВАТЬ** *несов.*— к. оттаять.

**ОТТА'ИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— эретелү; *мороженая рыба оттаивается в воде* — туң балык суда эретелә.

**ОТТА'ЛКИВАТЬ** *несов.*— к. оттолкнуть.

**ОТТА'ЛКИВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. оттолкнуться; 2. *страд.* этелү, этеп җибәрелү.

**ОТТА'ЛКИВАЮЩИЙ** — 1. этүче, этеп җибәрүче; 2. биздерә торган, сөйкемсез; *отталкивающий характер* — биздерә торган характер; *отталкивающая внешность* — сөйкемсез кыяфәт.

**ОТТАНЦОВА'ТЬ** *сов. разг.*— 1. (*исполнить танец*) танцевать итеп алу; 2. (*перестать танцевать*) танцевать итүдән туктау, танцевать итми башлау; 3. (*протанцовать известное время*) танцевать итеп үткәрү (берникадәр вакыт).

**ОТТАНЦОВА'ТЬСЯ** *сов. простореч.*— к. оттанцовать 2.

**ОТТА'ПЛИВАТЬ** *несов.*— к. оттопить.

**ОТТА'ПЛИВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. оттопиться; 2. *страд.* ягылу, ягып җылытылу.

**ОТТА'ПТЫВАТЬ** *несов.*— к. оттоптать.

**ОТТА'ПТЫВАТЬСЯ** *несов. страд.*— таптап бетерелү.

**ОТТАСКА'ТЬ** *сов.* — 1. *простореч.* илтеп кую, ташып кую, сөйрәп илтеп кую; *оттаскать мешки к сараю* — капчыкларны сарай янына сөйрәп илтеп кую; 2. (*закончить таскание*) ташып бетерү, ташудан туктау, сөйрәп илтеп бетерү; 3. *разг. фам.* тарту; *оттаскать за уши* — колагыннан тарткалау.

**ОТТАСКА'ТЬСЯ** *сов. простореч.*— к. оттаскать 2.

**ОТТА'СКИВАТЬ** *несов.*— к. оттаскать 1.

**ОТТА'СКИВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. оттащиться; 2. *страд.* илтеп куелу, ташылу, сөйрәп илтеп куелу.

**ОТТА'ЧИВАТЬ** *несов.*— к. отточить.

**ОТТА'ЧИВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. отточиться; 2. *страд.* үткенләндерелү, чарлану.

**ОТТАЩИ'ТЬ** *сов.*— 1. читкә сөйрәп алып китү; *оттащить бревно от ворот* — бүрәнәне капка яныннан читкә сөйрәп алып китү; 2. (*насильно отвести в сторону*) көчләп читкә алып китү.

**ОТТАЩИ'ТЬСЯ** *сов. разг. фам.*— көч-хәл белән китү, шуышып китү.

**ОТТА'ЯТЬ** *сов.*—1. эрү, эреп төшү; *земля оттаяла* — җир эрегән; *верёвка оттаяла от бочки* — бау мичкәдән эреп төшкән; 2. эретү; *оттаять замороженное мясо* — туң итне эретү.

**ОТТЕКА'ТЬ** *несов.*— к. оттечь.

**ОТТЕНИ'ТЬ** *сов.*— к. оттенять.

**ОТТЕ'НОК** *м.*— төсмер, оттенок, чагылыш.

**ОТТЕНЯ'ТЬ** *несов.*— 1. күләгәләү, күләгәләндерү; 2. *перен.* аеруча ачык итеп күрсәтү, күзгә бәрелеп торырлык итү; *писатель оттенил характерные черты героя* — язучы геройның характерлы билгеләрен аеруча ачык күрсәткән.

**ОТТЕНЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.*— 1. күләгәләндерелү; 2. *страд.* ачыкландырылу, күзгә бәрелеп торырлык ителү.

**О'ТТЕПЕЛЬ** *ж.*— җепшек көн.

**ОТТЕРЕБИ'ТЬ** *сов. разг.*— 1. тарткалап алу, йолыккалап бетерү; *оттеребить за волосы* — чәчләрен йолыккалап бетерү; 2. *спец.* йолкып бетерү; *оттеребить лён* — җитенне йолкып бетерү; 3. (*кончить теребление*) йолкудан туктау, йолкып бетерү.

**ОТТЕРЕ'ТЬ** *сов.*— 1. ышкып бетерү, уып бетерү; *оттереть пятно* — тапны уып бетерү; 2. *простореч.* кысрыклап чыгару, читкә этеп чыгару, юлына аркылы төшү; *его оттёрли назад* — аны кысрыклап артка чыгардылар; *его оттёрли более сильные конкуренты* — көчлерәк конкурентлар аның юлына аркылы төштеләр (аны кысрыклап чыгардылар); 3. уу, ышку; *оттереть обмороженную ногу снегом* — өшегән аякны кар белән уу.

**ОТТЕРЕ'ТЬСЯ** *сов.* — ышкылып бетү, уылып бетү; *пятно оттёрлось* — тап уылып беткән.

**ОТТЕСА'ТЬ** *сов.*—1. юнып алу, таслап алу, юнып төшерү; *оттесать края доски* — тактаның читләрен юнып алу; 2. юнып бетерү.

**ОТТЕСНИ'ТЬ** *сов.*— 1. кысрыклау, кысрыклап чыгару; *толпа меня оттеснила от трибуны* — халык төркеме мине трибуна яныннан кысрыклап чыгарды; 2. *воен.* чигендерү.

**ОТТЕСНЯ'ТЬ** *несов.*— к. оттеснить.

**ОТТЕСНЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.*— кысрыклап чыгарылу; чигендерелү.

**ОТТЁСЫВАТЬ** *несов.*— к. оттесать.

**ОТТЁСЫВАТЬСЯ** *несов. страд.*— юнып алыну, таслап алыну.

**ОТТЕ'ЧЬ** *сов.*— агып китү, читкә агып китү.

**ОТТИРА'ТЬ** *несов.*— к. оттереть.

**ОТТИРА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. оттереться; 2. *страд.* уып бетерелү, ышкып бетерелү.

**О'ТТИСК** *м.*— 1. оттиск; *корректурный оттиск* — корректура оттискысы; 2. *перен.* тәэсир, эз, йогынты; *оттиск в памяти* — күңелдә калган тәэсир.

**ОТТИ'СКАТЬ** *сов. разг.*— 1. таптау, изү, таптап бетерү; *ему оттискали ноги в толпе* — халык арасында аның аякларын таптап бетергәннәр; 2. *фам.* (*оттеснить*) кысрыклап чыгару.

**ОТТИ'СКАТЬСЯ** *сов. разг.*— этkәләшә-төрткәләшә чыгу, этkәләшеп-төрткәләшеп чыгу.

**ОТТИ'СКИВАТЬ** *несов.*— к. оттискать.

**ОТТИ'СКИВАТЬСЯ** *несов.*— 1. *разг.* к. оттискаться; 2. *страд.* кысрыклап чыгарылу.

**ОТТИ'СНУТЬ** *сов.*— 1. *разг.* этеп чыгару, кысрыклап чыгару; 2. *разг.* кысу, кыстыру; *оттиснуть палец дверью* — бармакны ишеккә кыстыру; 3. *тип.* басып алу, оттиск алу.

**ОТТОГО'** *нареч.*— шунлыктан, шуна күрә, ...-ганлыктан, ...-ганга күрә, ...-лыктан, шуның аркасында; *я был болен, оттого и не пришёл* — мин авыру идем, шунлыктан килә алмадым.

**ОТТО'К** *м. спец.*— улак, канау, труба (берәр нәрсәне агызып җибәрү өчен).

**ОТТО'ЛЕ** *нареч. книж. устар.*— к. оттуда.

**ОТТОЛКА'ТЬ** *сов. простореч.*— этkәләп җибәрү, этkәләп чыгару.

**ОТТОЛКНУ'ТЬ** *сов.*— 1. (*отпихнуть*)

этәреп җибәрү, этеп җибәрү; 2. *перен.* ераклаштыру, биздерү; *он оттолкнул людей своей грубостью* — тупаслыгы белән ул кешеләрне үзеннән биздерде; 3. күңел кайтару, ...-маска мәҗбүр итү; *трудность пути многих оттолкнула от поездки* — юлның авырлыгы күп кешеләрне бармаска мәҗбүр итте.

**ОТТОЛКНУ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. этәрелеп кузгалып китү; *оттолкнуться от берега* — этәрелеп ярдан кузгалып китү; 2. *перен. книж.* читкә ташлау, таянмый башлау; *оттолкнуться от чужой идеи* — кеше идеясенә таянмый башлау.

**ОТТОЛКОВА'ТЬ** *сов. разг.*— аңлатма бирүдән туктау, сүзне бетерү.

**ОТТО'ЛЬ** *нареч. книж. устар.*— к. оттуда.

**ОТТОМА'НКА** *ж.*— оттоманка (киң йомшак диван).

**ОТТО'ПАТЬ** *сов.*— 1. *разг. фам.* к. оттоптать 1; 2. (*кончить топать*) таптаудан туктау, йөрүдән туктау.

**ОТТОПИ'ТЬ** *сов. разг.*— 1. (*кончить топить*) ягудан туктау, якмый башлау; 2. эретеп аерып алу, эретеп алу; *оттопить все примеси из сала* — туң майны эретеп барлык катнашмаларын аерып алу.

**ОТТОПИ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. *разг.* к. истопиться; 2. *простореч.* к. оттопить 1.

**ОТТО'ПКИ** *ед.* нет, *спец.*— турта, сызык (эретүдән соң калган калдыклар); *оттопки от сала* — май сызыклары (эреткәннән соң калган).

**ОТТОПТА'ТЬ** *сов. разг. шутл.*— 1. (*повредить ходьбой, топтанием*) йөреп аякка зыян китерү; 2. (*повредить, наступая ногой*) басып авырттыру, аяк белән басып зыян китерү.

**ОТТОПЫ'РИВАТЬ** *несов. разг.*— к. оттопырить.

**ОТТОПЫ'РИВАТЬСЯ** *несов. разг.*— 1. к. оттопыриться; 2. *страд.* турсайтылу, ерылу, тырпайтылу.

**ОТТОПЫ'РИТЬ** *сов. разг.*— тырпайту, турсайту; кабарту; *оттопырить губы* — иренне турсайту; *оттопырить карман* — кесәне кабарту.

**ОТТОПЫ'РИТЬСЯ** *сов. разг.*— тырпаю, турсаю, кабару.

**ОТТОРГА'ТЬ** *несов. книж. ритор.*— к. отторгнуть.

**ОТТОРГА'ТЬСЯ** *несов. страд. книж. ритор.* — тартып алыну, көчләп тартып алыну.

**ОТТО'РГНУТЬ** *сов. книж. ритор.*— тартып алу, көчләп тартып алу, аерып алу, аеру; *отторгнуть чужие земли* — чит җирләрне тартып алу.

**ОТТОРГОВА'ТЬ** *сов. разг.*— сәүдә итүдән туктау, сәүдә итүне ташлау, сәүдә итү белән шөгыльләнми башлау.

**ОТТО'ЧИЕ** *ср. тип.*— нокталар тезмәсе, бик күп нокталар (нагорда).

**ОТТОЧИ'ТЬ** *сов.*— 1. кайрау, үткенләү, чарлау, үткенләп кую, очлау; *отточить нож* — пычак кайрау, пычакны үткенләү; 2. үткенләп бетерү, чарлап бетерү.

**ОТТОЧИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — үткенләнү, чарлану, очлану; *нож хорошо отточился* — пычак яхшы үткенләнгән.

**ОТТРЕПА'ТЬ** *сов.*— 1. (*наказать, дёргая за волосы, шерсть*) тарту, тарткалау; 2. талкып бетерү; *оттрепать лён* — житенне талкып бетерү. ◇ **Оттрепать за ухо** — колагын бору.

**ОТТРЁПЫВАТЬ** *несов.*— к. оттрепать.

**ОТТРЁПЫВАТЬСЯ** *несов. страд.*— талкып бетерелү.

**ОТТРУБИ'ТЬ** *сов.*— 1. трубада уйнап сигнал бирү; 2. *перен. разг. фам.* вакыт үткәрү; *три часа оттрубил сегодня в очереди за билетами* — бүген билетка чират торып өч сәгать вакыт үткәрдем.

**ОТТРЯСТИ'** *сов. разг.*— кагып чистарту, селкеп чистарту.

**ОТТРЯ'ХИВАТЬ** *несов. разг.*— к. оттрясти.

**ОТТРЯХНУ'ТЬ** *разг. однокр.*— кагып төшерү, селкеп төшерү (мәсәлән, кунган тузанны).

**ОТТУ'ДА** *нареч.*— 1. аннан, шуннан, шул урыннан, теге яктан; *откуда ветер, оттуда и дождь* — җил кайсы яктан булса, яңгыр да шуннан; 2. (*вследствие того, по причине того*) шул сәбәпле, шунлыктан, шуңа күрә.

**ОТТУЖИ'ТЬ** *сов. разг.*— кайгы-хәсрәт чигүдән туктау, кайгырмый башлау.

**ОТТУЗИ'ТЬ** *сов. разг.*— тукмап ташлау, дөмбәсләп ташлау.

**ОТТУШЕВА'ТЬ** *сов.*— 1. (*наложить тени к чему-н.*) күләгәләү, күләгә төшерү (рәсемдә); 2. (*закончить тушовку*) тушь салуны тәмамлау.

**ОТТУШЁВЫВАТЬ** *несов. спец.*— к. оттушевать.

**ОТТУШЁВЫВАТЬСЯ** *несов. страд. спец.*— 1. күләгәләнү, күләгә төшерелү; 2. тушь салынып бетерелү.

**ОТТЫКА'ТЬ** *сов. простореч.*— к. ототкнуть.

**ОТТЫКА'ТЬСЯ** *несов. страд. простореч.*— бөкесе чыгарылу, тыккычы чыгарылу.

**ОТТЮ'КАТЬ** *сов. разг. фам. шутл* — ватып төшерү, сындырып төшерү; *оттюкать ручку у чайника* — чәйнекнең тогкасын ватып төшерү.

**ОТТЮ'КНУТЬ** *сов. разг. фам. шутл.*— к. оттюкать.

**ОТТЯГА'ТЬ** *сов. простореч.*— дәгъвалашып кайтарып алу, тартышып кайтарып алу.

**ОТТЯ'ГИВАТЬ** *несов.*— к. оттянуть.

**ОТТЯ'ГИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— 1. читкә тартылу, читкә алып кителү; 2. озакка суздырылу.

**ОТТЯНУ'ТЬ** *сов.*— 1. читкә тарту, читкә алып китү; *оттянуть верёвку в сторону* — бауны читкә тарту; 2. *воен.* (читкә) алып китү; *оттянуть часть пехоты с левого фланга* — пехотаның бер өлешен сул флангтан алып китү; 3. *перен.* кичектерү, озакка сузу; *оттянуть решение* — хәл итүне озакка сузу; 4. *тех.* сузу, чүкеп озынайту; *оттянуть болт* — болтны чүкеп озынайту; 5. *разг.* турсайту; *оттянуть губы* —

иренне турсайту; 6. *разг.* авырттыру (авыр нәрсә күтәреп); *оттянуть руку тяжёлым чемоданом* — авыр чемодан күтәреп кулны авырттыру.

**ОТТЯ'ПАТЬ** *сов. простореч.* — чабып өзү, чабып төшерү, кисеп төшерү; кисеп ташлау; *оттяпать палец топором* — бармакны балта белән чабып өзү.

**ОТТЯ'ПНУТЬ** *сов. однокр. простореч.* — к. оттяпать.

**ОТТЯ'ПЫВАТЬ** *несов. простореч.* — к. оттяпать.

**ОТТЯ'ПЫВАТЬСЯ** *несов. страд. простореч.* — чабып өзелү, чабып төшерелү, кисеп төшерелү.

**ОТУДИ'ТЬ** *сов.* — балык тотудан туктау.

**ОТУ'ЖИНАТЬ** *сов.* — 1. (*кончить ужинать*) кичке ашны ашап бетерү; 2. *устар.* (*поужинать*) кичке ашны ашап алу.

**ОТУМА'НИВАТЬ** *несов.* — к. отуманить.

**ОТУМА'НИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. отуманиться; 2. *страд.* томанлану, караңгылану.

**ОТУМА'НИТЬ** *сов.* — 1. *нар.-поэт.* томанландыру, караңгыландыру, каплау; *глаза слезами отуманило* — күзләрне яшь томанландырды; 2. *перен.* (*затемнить сознание*) башын әйләндерү, исен китәрү, акылдан яздыру, башын бутау, зиһенен чуалту.

**ОТУМА'НИТЬСЯ** *сов.* — 1. *поэт.* (*застлаться туманом*) томанлану, караңгылану; 2. *перен.* башы әйләнү, баш буталу; зиһен чуалу.

**ОТУПЕ'ЛЫЙ** *разг.* — аңгыраланган, миңгерәүләнгән.

**ОТУПЕ'ТЬ** *сов. разг.* — аңгыралану, миңгерәүләнү.

**ОТУТЮ'ЖИВАТЬ** *несов.* — к. отутюжить.

**ОТУТЮ'ЖИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — үтүкләнү, үтүкләп чыгылу.

**ОТУТЮ'ЖИТЬ** *сов.* — 1. үтүкләү; 2. (*закончить утюжку*) үтүкләп бетерү; 3. *перен. простореч. вульг.* (*избить*) тукмап ташлау, кирәген бирү, каезлап ташлау.

**ОТУЧА'ТЬ** *несов.* — к. отучить.

**ОТУЧА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. отучиться 1; 2. *страд.* биздерелү.

**ОТУ'ЧИВАТЬ** *несов. разг.* — к. отучить 2.

**ОТУ'ЧИВАТЬСЯ** *несов. простореч.* — к. отучиться 2.

**ОТУЧИ'ТЬ** *сов.* — 1. биздерү, ташлату; *его отучили курить* — аны тәмәке тартудан биздергәннәр; 2. (*закончить уроки*) дәресләрне бетерү, дәрес бирүне тәмам итү.

**ОТУЧИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. бизү, ташлау; *отучиться курить* — тәмәке тартуны ташлау; 2. *простореч.* (*об ученике*) дәресләрне хәзерләп бетерү.

**ОТУЧНЕ'ТЬ** *сов. разг. редко* — калынаеп китү, симереп китү, юанаеп китү.

**ОТФОРМОВА'ТЬ** *сов. тех.* — формага кою, калыпка кою.

**ОТФОРМО'ВЫВАТЬ** *несов. тех.* — к. отформовать.

**ОТФОРМО'ВЫВАТЬСЯ** *несов. страд. тех.* — формага коелу, калыпка коелу.

**ОТФРЕЗЕРОВА'ТЬ** *сов.* — фрезерлап чыгу, фрезерлау.

**ОТХА'ЖИВАТЬ** *несов.* — к. отходить 2.

**ОТХА'ЖИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — тәрбияләп терелтелү, тәрбияләп сәламәтләндерелү, савыктырылу.

**ОТХА'РКАТЬ** *сов. разг.* — 1. какыру, какырып чыгару; 2. (*кончить харкать*) какырудан туктау, какырып туктау.

**ОТХА'РКАТЬСЯ** *сов.* — какырып бетерү.

**ОТХА'РКИВАТЬ** *несов.* — к. отхаркать.

**ОТХА'РКИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. отхаркаться; 2. *страд.* какырып чыгарылу.

**ОТХА'РКИВАЮЩИЙ** *мед.* — какырып чыгарта торган, какырта торган (дару).

**ОТХА'РКНУТЬ** *сов.* — какырып чыгару.

**ОТХВАТА'ТЬ** *сов. разг. фам.* — өзеп-өзеп алу, кыркып-кыркып алу.

**ОТХВАТИ'ТЬ** *сов. разг.* — 1. өзеп алу, кисеп алу, умырып алу; *он ножницами отхватил себе волосы* — ул кайчы белән үзенең чәчен кисеп алды; 2. ...-п алу; *отхватить трепака* — трепакны биеп алу.

**ОТХВА'ТЫВАТЬ** *несов. разг.* — к. отхватить, отхватать.

**ОТХВА'ТЫВАТЬСЯ** *несов. страд. разг.* — өзеп алыну, кисеп алыну, кыркып алыну.

**ОТХВОРА'ТЬ** *сов. разг.* — терелү, савыгу, сәламәтләнү.

**ОТХЛЕБА'ТЬ** *сов. разг.* — ашап бетерү (сыек ашны).

**ОТХЛЕБНУ'ТЬ** *сов. разг.* — бераз эчеп алу, эчеп җибәрү.

**ОТХЛЁБЫВАТЬ** *несов.* — аз-азлап эчү.

**ОТХЛЕСТА'ТЬ** *сов. разг.* — 1. камчылау, чыбыркылау (камчы белән кыйнау, чыбыркы белән кыйнау); 2. *перен. вульг.* (*отругать резко*) ачуланып тиргәү, ачу белән тәнкыйтьләү, орышу.

**ОТХЛЁСТЫВАТЬ** *несов. разг.* — к. отхлестать.

**ОТХЛО'ПАТЬ** *сов. разг.* — 1. (*перестать аплодировать*) алкышлаудан туктау, кул чабудан туктау; 2. *разг.* кул чабып кулны авырттырып бетерү; 3. *фам.* (*побить, поколотить*) тукмап ташлау, кыйнап ташлау; 4. *простореч.* туздырып бетерү; *отхлопать кнут* — чыбыркыны туздырып бетерү.

**ОТХЛО'ПЫВАТЬ** *несов.* — к. отхлопать.

**ОТХЛЫ'НУТЬ** *сов.* — 1. кире китү, бәрелеп кире агып китү; *волны отхлынули от берега* — дулкыннар ярга бәрелеп кире агып киттеләр; 2. *разг.* читкә тайпылу, читкә китү; читкә ташлану, артка чигенү; *колонны противника отхлынули от крепости* — дошман колонналары крепостьтан артка чигенделәр.

**ОТХЛЫСТА'ТЬ** *сов. простореч.* — к. отхлестать.

**ОТХЛЫ'СТЫВАТЬ** *несов. простореч.* — к. отхлестать.

**ОТХО'Д** I *м.* — 1. *только ед.* китү; *отход поезда* — поездның китүе; 2. *воен.* чигенү, чигү; *отход частей на заранее приготовленные позиции* — гаскәрләрнең алдан хәзерләнгән позицияләргә чигенүе; 3. *книж.* ераклашу, аерылу, читкә китү; *отход от масс* — массалардан ераклашу.

**ОТХО'Д** II *м. чаще мн. спец.* — 1. кал-

дык-постык (производствода); 2. койрык (ашлык суырганда); 3. *спец.* үлү, кырылу (терлекләрнең үстергәндә үлүе).

**ОТХОДИ'ТЬ** I *несов.* — к. отойти.

**ОТХОДИ'ТЬ** II *сов.* — 1. *(вылечить уходом)* тәрбияләп терелтү, тәрбияләп сәламәтләндерү, тәрбияләп савыктыру; 2. *разг.* йөреп талдыру, йөреп авырттыру, йөреп авырттырып бетерү; *я- то уж ноги отходила* — мин инде йөри-йөри аякларымны авырттырып бетердем; 3. *разг.* йөрми башлау, йөрүдән туктау; *уж давно он отходил в свою канцелярию* — ул күптән инде үзенең канцеляриясенә йөрми башлады; 4. *разг.* йөреп үткәрү; *вот уже второй год отходил мальчик в школу* — малай ике елын мәктәпкә йөреп үткәрде инде.

**ОТХО'ДНАЯ** *ж. церк.* — үлгән кеше өстендә дога уку.

**ОТХО'ДНИК** *м.* — 1. читкә эшкә киткән крестьян; 2. *устар.* *(ассенизатор)* шакшылар түгүче.

**ОТХО'ДНИЧЕСТВО** *ср. мн.* нет — читкә эш эзләп китү, читкә эшкә китү.

**ОТХО'ДЧИВЫЙ** — ачуы тиз басыла торган, тиз кайтучан; *отходчивый человек* — тиз кайтучан кеше.

**ОТХО'ЖИЙ** *устар.*: **отхожий промысел** — читкә китеп эшләү; **отхожее место** *разг.* — бәдрәф, әбрәкәй.

**ОТХОТЕ'ТЬ** *сов. разг.* — теләми башлау, теләгеннән кире кайту, теләге бетү.

**ОТЦА'РСТВОВАТЬ** *сов. разг.* — патшалык итүдән туктау, патшалыктан төшү.

**ОТЦВЕСТИ'** *сов.* — 1. чәчәк атып бетерү; *травы отцвели* — үләннәр чәчәк атып бетерделәр; 2. *перен.* шиңү, пәжү, сулу.

**ОТЦЕДИ'ТЬ** *сов.* — 1. сөзеп алу, сөзеп киметү; *отцедить ковш квасу из бочки* — мичкәдән бер чүмеч квас сөзеп алу; 2. *(удалить, процеживая)* сөзеп чистарту, сөзеп алып ташлау.

**ОТЦЕ'ЖИВАТЬ** *несов.* — к. отцедить.

**ОТЦЕ'ЖИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. сөзеп алыну; 2. сөзеп киметелү, сөзеп алып ташлану.

**ОТЦЕПИ'ТЬ** *сов.* — 1. ычкындыру; ычкындырып алу; *отцепить вагон* — вагонны ычкындыру; *отцепить брошку* — брошканы ычкындырып алу; 2. алып ташлау; *отцепить репейник* — тигәнәкне алып ташлау.

**ОТЦЕПИ'ТЬСЯ** *сов.* — ычкынып китү, ычкыну; *вагон отцепился* — вагон ычкынып китте. ◇ **Отцепись ты от меня** — бәйләнмә син миңа.

**ОТЦЕПЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. отцепить.

**ОТЦЕПЛЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. отцепиться; 2. *страд.* ычкындырып алыну, алып ташлану.

**ОТЦЕПНО'Й** — ычкындырыла торган, ычкындырып алына торган; *отцепная цепочка* — ычкындырыла торган чылбыр.

**ОТЦЕ'ПЩИК** *м.* — ычкындыручы.

**ОТЦЕУБИ'ЙЦА** *м.* и *ж.* — атасын үтергән кеше.

**ОТЦО'ВСКИЙ** — 1. ата ...-ы; *отцовский дом* — ата йорты; 2. аталык ...-ы; *отцовские чувства* — аталык тойгылары.

**ОТЦО'ВСТВО** *ср. мн.* нет, *книж. офиц.* — аталык.

**ОТЧАЁВНИЧАТЬ** *сов. простореч.* — чәй эчеп бетерү.

**ОТЧА'ИВАТЬСЯ** *несов.* — к. отчаяться.

**ОТЧА'ЛИВАТЬ** *несов.* — к. отчалить. ◇ **Отчаливай!** *простореч. фам.* — тай моннан, ычкын, бәйләнмә, үкчәңне күтәр.

**ОТЧА'ЛИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. отчалиться; 2. *страд.* чалкалар ычкындырылу.

**ОТЧА'ЛИТЬ** *сов.* — 1. *(отвязать причал)* чалкаларны чишеп җибәрү, чалкаларны чишү; 2. *разг.* *(отойти, отъехать)* кузгалып китү (ярдан судноләр).

**ОТЧА'ЛИТЬСЯ** *сов.* — ычкыну (чалкалар турында).

**ОТЧА'СТИ** *нареч.* — берникадәр, бераз, бер яктан, кисәкчә; *он прав только отчасти* — ул бер яктан гына хаклы.

**ОТЧА'ЯНИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — рух төшү, өметсезлек, өметсезләнү; *придти в отчаяние* — өметсезлеккә төшү.

**ОТЧА'ЯННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *разг.* — үтә тәвәккәллек, үтә кыюлык, чаялык.

**ОТЧА'ЯННЫЙ** — 1. *(смелый до безрассудства)* үтә тәвәккәл, артык кыю, чая, башсыз; 2. *(крайний по своей силе проявления)* чиктән ашкан, актык чиккә җиткән, өметсез; 3. *разг. фам.* *(очень плохой)* бик әшәке; 4. *книж.* өметсез; *отчаянный взор* — өметсез караш.

**ОТЧА'ЯТЬСЯ** I *сов. книж.* — өмет өзү, өметсезлеккә төшү.

**ОТЧА'ЯТЬСЯ** II *сов. простореч. шутл.* — к. отчаёвничать.

**ОТЧЕГО'** *нареч.* — ни сәбәптән, ни өчен, нигә, нилектән, нәрсәдән.

**ОТЧЕГО'-ЛИБО** *нареч. книж.* — к. отчего-нибудь.

**ОТЧЕГО'-НИБУДЬ** и **ОТЧЕГО'-НИБУ'ДЬ** *нареч.* — берәр сәбәптән, берәр сәбәп аркасында, ни өчен дә булса.

**ОТЧЕГО-ТО'** *нареч.* — ни сәбәптәндер, ни өчендер, нигәдер.

**ОТЧЕКА'НИВАТЬ** *несов.* — к. отчеканить.

**ОТЧЕКА'НИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. коелу, сугылу (мәсәлән, акча); 2. *перен.* ачык итеп әйтелү.

**ОТЧЕКА'НИТЬ** *сов.* — 1. кою, сугу; *отчеканить серебряную монету* — көмеш акча сугу; 2. *(кончить чеканить)* коеп бетерү, сугып бетерү; 3. *перен.* аермачык итеп әйтү, һәр авазын ачык итеп әйтү.

**ОТЧЕКРЫ'ЖИТЬ** *сов. простореч. шутл.* — кисеп алу, чабып өзү, кисеп төшерү; *чуть палец топором не отчекрыжил* — чак кына бармагымны балта белән чабып өзмәдем.

**ОТЧЁРКИВАТЬ** *несов.* — к. отчеркнуть.

**ОТЧЁРКИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — сызык белән аерып алыну, сызык белән билгеләнү.

**ОТЧЕРКНУ'ТЬ** *сов.* — 1. *(отделить чертою)* сызык белән аерып алу; 2. сызып

кую; *отчеркнуть интересные места в статье* — мәкаләдәге кызыклы урыннарны сызып кую.

**ОТЧЕ'РПАТЬ** *сов.* — 1. сосып алу, сосып алып бетерү; 2. *(прекратить работу по черпанию)* сосып алудан туктау.

**ОТЧЕРПНУ'ТЬ** *сов. разг.* — сосып алып киметү, сосып алып киметә төшү.

**ОТЧЕ'РПЫВАТЬ** *несов.* — к. отчерпнуть, отчерпать.

**ОТЧЕ'РПЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — сосып алып киметелү, сосып алып киметелә төшү.

**ОТЧЕРТИ'ТЬ** *сов.* — 1. *(отделить чертой)* сызып билгеләү, сызып билгеләп кую; 2. сызып бетерү; *отчертить схему* — схеманы сызып бетерү; 3. *(кончить чертёжную работу)* чертёж ясауны тәмамлау, чертёж ясаудан туктау.

**ОТЧЕ'РЧИВАТЬ** *несов.* — к. отчертить.

**ОТЧЕ'РЧИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. сызып билгеләп куелу; 2. сызып бетерелү, чертёж ясап бетерелү.

**ОТЧЕСА'ТЬ** *сов.* — 1. тарап бетерү, тарауны тәмамлау, тараудан туктау; 2. *простореч. (избить, высечь)* тукмап ташлау, кыйнап ташлау; 3. *простореч. вульг. (грубо выругать)* тетмәсен тетү (тупас рәвештә тиргәү, сүгеп ташлау).

**ОТЧЕСА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — таралу; *лён хорошо отчесался* — житен яхшы таралган.

**О'ТЧЕСКИЙ** *устар.* — к. отцовский.

**О'ТЧЕСТВО** *ср.* — атасының исеме.

**ОТЧЁСЫВАТЬ** *несов.* — к. отчесать.

**ОТЧЁСЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. отчесаться; 2. *страд.* тарап бетерелү.

**ОТЧЁТ** *м.* — отчёт, хисап, исәп-хисап; *отчёт о командировке* — командировка турында отчёт. ◇ **Дать или отдать себе отчёт** — үзенә-үзең хисап бирү, аңлау. **Не давая себе отчёта** — аңсыз рәвештә, белештермичә. **Под отчёт** *офиц.* — соңыннан отчёт бирү шарты белән (акча алу).

**ОТЧЁТИСТЫЙ** *простореч.* — к. отчётливый.

**ОТЧЁТЛИВОСТЬ** *ж. мн.* нет — аныклык, ачыклык; *отчётливость мысли* — фикернең ачыклыгы.

**ОТЧЁТЛИВЫЙ** — җиренә җиткереп эшләнгән, ачык, аңлаешлы, анык, ачык итеп...; *отчётливое движение* — җиренә җиткереп эшләнгән хәрәкәт; *отчётливый рисунок* — ачык рәсем; *отчётливое произношение* — анык әйтелеш; *отчётливое представление* — ачык итеп күз алдына китерү.

**ОТЧЁТНО-ВЫ'БОРНЫЙ** — отчёт-сайлау ...-ы; *отчётно-выборное собрание* — отчёт-сайлау җыелышы.

**ОТЧЁТНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *спец.* — 1. хисап бирү, отчёт бирү; 2. *разг.* расходларны раслый торган документлар җыентыгы.

**ОТЧЁТНЫЙ** *офиц. канц.* — отчёт...-ы, отчётлар төзү ...-ы; *отчётная кампания* — отчёт кампаниясе.

**ОТЧИ'ЗНА** *ж. мн.* нет, *высок.* — ватан, туган ил.

**О'ТЧИЙ** *книж. поэт. устар.* — к. отцовский.

**О'ТЧИМ** *м.* — үги ата.

**О'ТЧИНА** *ж. истор.* — к. вотчина.

**О'ТЧИННИК** *м. истор.* — к. вотчинник.

**О'ТЧИННЫЙ** *истор.* — к. вотчинный.

**ОТЧИРИ'КАТЬ** *сов. разг.* — череддәүдән туктау.

**ОТЧИСЛЕ'НИЕ** *ср. канц.* — 1. *только ед. (действие)* к. отчислить; 2. *(отчисленная сумма)* отчисление ясап чыгарылган сумма.

**ОТЧИ'СЛИТЬ** *сов. офиц.* — 1. чигерү, аерып кую; *отчислить тысячу рублей* — мең сум чигерү, мең сум аерып кую (нинди дә булса бер расходка); 2. *(уволить)* хезмәттән чыгару.

**ОТЧИ'СЛИТЬСЯ** *сов. офиц.* — хезмәттән чыгу.

**ОТЧИСЛЯ'ТЬ** *несов. офиц.* — к. отчислить.

**ОТЧИСЛЯ'ТЬСЯ** *несов. офиц.* — 1. к. отчислиться; 2. *страд.* исәпләп чыгарылу, күчерелү; 3. хезмәттән чыгарылу.

**ОТЧИ'СТИТЬ** *сов.* — 1. чистарту, тазарту; 2. *(кончить чистить)* тазартып бетерү, чистартып бетерү.

**ОТЧИ'СТИТЬСЯ** *сов. разг.* — чистару; *пальто отчистилось хорошо* — пальто яхшы чистарган.

**ОТЧИТА'ТЬ** *сов. разг.* — 1. шелтәләү, орышу, әрләү, кыздыру; 2. укып чыгу, укудан туктау (берәр нәрсәне).

**ОТЧИТА'ТЬСЯ** *сов.* — хисап бирү; отчёт бирү.

**ОТЧИ'ТЫВАТЬ** *несов.* — к. отчитать.

**ОТЧИ'ТЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. отчитаться; 2. *страд.* шелтәләнү, кыздырылу.

**ОТЧИХА'ТЬ** *сов. разг.* — төчкереп бетерү, төчкерүдән туктау.

**ОТЧИХА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — төчкереп борынны чистарту.

**ОТЧИХВО'СТИТЬ** *сов. простореч. фам.* — бик каты итеп тиргәү, каты итеп шелтәләү.

**ОТЧИ'ХИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — к. отчихаться.

**ОТЧИЩА'ТЬ** *несов.* — к. отчистить.

**ОТЧИЩА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. *разг.* к. отчиститься; 2. *страд.* тазартып бетерелү.

**ОТЧУБУ'ЧИТЬ** *сов. простореч. устар.* — тукмау, дөмбәсләү, пешерү.

**ОТЧУДИ'ТЬ** *сов. офиц. редко* — к. отчуждать.

**ОТЧУЖДА'ТЬ** *несов. офиц.* — тартып алу (дәүләт яисә җәмәгать оешмалары карамагына тапшыру өчен).

**ОТЧУЖДА'ТЬСЯ** *несов.* — *офиц. страд.* тартып алыну.

**ОТЧУЖДЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — 1. *офиц. (действие)* к. отчуждать; 2. *книж.* ераклашу, читләшү, ят итү; *взаимное отчуждение* — бер-береннән ераклашу.

**ОТЧУЖДЁННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — читләшү, ераклашу, ят булу.

**ОТЧУЖДЁННЫЙ** *офиц.* — 1. ераклашкан,

читләшкән; 2. *книж.* кешеләр белән аралашмаучан, кешеләр белән аралашмый торган; *отчуждённый человек* — кешеләр белән аралашмаучан кеше.

**ОТШАГА'ТЬ** *сов. фам. разг.* — 1. *(пройти какое-н. расстояние пешком)* җәяү бару, җәяү йөреп чыгу, җәяү йөреп үткәрү (вакытны); 2. *(кончить шагать, маршировать)* җәяү йөрүдән туктау, маршировать итүдән туктау.

**ОТША'ГИВАТЬ** *несов. разг. фам.* — к. отшагать.

**ОТШАГНУ'ТЬ** *сов. разг.* — бер адым читкә атлау; берничә адымга читкә китү.

**ОТШАТНУ'ТЬ** *сов. разг.* — 1. боргалап сындырып алу, какшатып төшерү; *отшатнуть повисший сук дерева* — асылынып торган ботакны боргалап сындырып алу; 2. *перен.* биздерү, качыру; ераклаштыру; *отшатнуть от себя друзей своим поведением* — үзен начар тоту аркасында дусларын ераклаштыру.

**ОТШАТНУ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. *(резким движением отступить)* читкә тайпылу, кинәт артка чигенү; 2. *перен.* мөнәсәбәтне өзү, йөз чөерү, читләшү, аралашмый башлау, бизү; *друзья отшатнулись от него* — дуслары аңардан йөз чөергәннәр (дуслары аның белән мөнәсәбәтне өзгәннәр).

**ОТШВЫ'РИВАТЬ** *несов. разг.* — к. отшвырнуть.

**ОТШВЫ'РИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. к. отшвыряться; 2. *страд.* ыргытып җибәрелү, этеп җибәрелү, читкә ыргытылу, тәртеп җибәрелү.

**ОТШВЫРНУ'ТЬ** *сов. разг.* — ыргытып җибәрү, этеп җибәрү, тәртеп җибәрү, читкә ыргыту; *отшвырнуть камень в сторону* — ташны читкә ыргытып җибәрү.

**ОТШВЫРЯ'ТЬ** *сов. разг.* — ыргытып бетерү, читкә ыргытып бетерү.

**ОТШВЫРЯ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. бәреп котылу, ыргытып котылу; *отшвыряться от собак камнями* — ташлар бәреп этләрдән котылу; 2. *простореч.* к. отшвырять.

**ОТШЕ'ЛЬНИК** *м.*, **ОТШЕ'ЛЬНИЦА** *ж. книж.* — 1. *устар.* дәрвиш, суфый, аскет (кешеләр белән аралашудан баш тартучы монах); 2. *перен. ирон.* ялгыз яшәүче, кешегә катышмаучы, кешеләр белән аралашмаучы.

**ОТШЕ'ЛЬНИЧЕСКИЙ** *устар. ирон.* — дәрвишләр...-ы, дәрвишләрчә...; *отшельническая жизнь* — дәрвишләр тормышы, дәрвишләрчә тормыш.

**ОТШЕ'ЛЬНИЧЕСТВО** *ср. мн.* нет, *устар. ирон.* — дәрвишләр тормышы.

**О'ТШИ'Б** *м.*: на отшибе *разг. обл.* — 1. читтә, авыл читендә; *изба стояла на отшибе* — өй авыл читендә тора иде; 2. *перен.* читтә; *живёт на отшибе* — читтә тора.

**ОТШИБА'ТЬ** *несов. разг.* — к. отшибить.

**ОТШИБА'ТЬСЯ** *несов. страд. разг.* — бәреп төшерелү, бәреп ватылу, бәреп имгәтелү, бәреп кире җибәрелү.

**ОТШИБИ'ТЬ** *сов. разг.* — 1. бәреп вату, бәреп төшерү; *отшибить ручку у чайника* — чәйнекнең тоткасын бәреп төшерү; 2. бәреп имгәтү; *отшиб себе руку* — бәреп кулымны имгәттем; 3. бәреп кире җибәрү; *ловко отшиб мяч* — тупны бик оста итеп кире бәреп җибәрде; 4. *фам.* югалту, бетү; *ему отшибло память* — ул хәтерен югалткан, аның хәтере беткән.

**ОТШИВА'ТЬ** *несов.* — к. отшить.

**ОТШИВА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. отшиться; 2. *страд.* кубарып алыну.

**ОТШИ'ТЬ** *сов.* — 1. *плот.* кубарып алу; *отшить доски* — такталарны кубарып алу; 2. *простореч. фам.* куып җибәрү; *она отшила его* — ул аны куып җибәрде; 3. *(кончить шить)* тегеп бетерү; 4. *(кончить шитьё)* тегүне тәмамлау.

**ОТШИ'ТЬСЯ** *сов. простореч.* — 1. сүтелеп төшү (тегеп куелган нәрсә турында); 2. *фам. (отстраниться, отойти)* читкә китү, аралашмау, катнашмау; 3. к. отшить 3.

**ОТШЛЁПАТЬ** *сов.* — 1. *разг. фам. (надавать шлепков)* бәргәләп алу, чабаклау, суккалап алу; 2. *простореч. (загрязнить)* пычратып бетерү; 3. *разг. шутл.* пычрак ерып бару; *отшлёпал целый километр* — бер километр пычрак ерып бардым.

**ОТШЛЁПЫВАТЬ** *несов.* — к. отшлёпать.

**ОТШЛИФОВА'ТЬ** *сов.* — шомарту, шомартып ялтырату, шлифовать итү; *отшлифовать гранит* — гранитны шомартып ялтырату.

**ОТШЛИФОВА'ТЬСЯ** *сов.* — 1. шомару, шомарып ялтырау; 2. *перен. разг. фам.* шомару; *отшлифовался в городе* — шәһәрдә торып шомарган.

**ОТШЛИФО'ВЫВАТЬ** *несов.* — к. отшлифовать.

**ОТШЛИФО'ВЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. отшлифоваться; 2. *страд.* шомартылу, шомартып ялтыратылу.

**ОТШПАНДО'РИТЬ** *сов. простореч. фам.* — суктыру, тукмап ташлау.

**ОТШПИ'ЛИВАТЬ** *несов.* — к. отшпилить.

**ОТШПИ'ЛИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. отшпилиться; 2. *страд.* шпилькалары алыну, шпилькалары ычкындырылу.

**ОТШПИ'ЛИТЬ** *сов.* — шпилькаларны алу, шпилькаларны ычкындыру, ычкындыру; *отшпилить бант* — бантны ычкындыру.

**ОТШПИ'ЛИТЬСЯ** *сов.* — шпилькалары төшү, шпилькалары ычкынып төшү.

**ОТШТО'ПАТЬ** *сов.* — штопать итеп чыгу.

**ОТШТУКАТУ'РИТЬ** *сов. спец.* — штукатурлап бетерү.

**ОТШУМЕ'ТЬ** *сов.* — тавышланудан туктау, шаулаудан туктау.

**ОТШУТИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — шаярып җавап бирү, шаярып җавап биреп котылу, шаярып котылу; *он отшутился* — ул шаярып котылды.

**ОТШУ'ЧИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — к. отшутиться.

**ОТЩЁЛКАТЬ** *сов.* — 1. *простореч.* к. отщелка́ть 1; 2. сайраудан туктау, сайрап туктау; *соловей отщёлкал* — сандугач сайрап туктады.

**ОТЩЕЛКА'ТЬ** *сов. простореч.* — 1. чырткәләү (чыртеп авырттыру); 2. *перен.* бик нык тиргәү.

**ОТЩЁЛКИВАТЬ** *несов.*— к. отщелкнуть.
**ОТЩЕЛКНУ'ТЬ** *сов. разг.*— келәсен ычкындыру, ачу; *отщелкнуть дверь*— ишекнең келәсен ычкындыру (ачу).
**ОТЩЕМИ'ТЬ** *сов. разг.*— кысу, кыстырып авырттыру; *отщемить палец в дверях* — бармакны ишеккә кысу.
**ОТЩЕМЛЯ'ТЬ** *несов. разг.*— к. отщемить.
**ОТЩЕМЛЯ'ТЬСЯ** *несов. страд. разг.*— кыстырылу.
**ОТЩЕПА'ТЬ** *сов. разг.*— ярып алу, телеп алу; *отщепать немного лучин* — бераз чыра телеп алу.
**ОТЩЕПЕ'НЕЦ** *м.*, **ОТЩЕПЕ'НКА** *ж. книж. презрит.*— мөртәт, куылган кеше, кире кагылган кеше (җәмгыять тарафыннан).
**ОТЩЕПЕ'НСТВО** *ср. мн.* нет, *книж. презрит.*— мөртәтлек.
**ОТЩЕПИ'ТЬ** *сов.*— ярып алу, телеп алу.
**ОТЩЕПЛЯ'ТЬ** *несов.*— к. отщепить.
**ОТЩЕПЛЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — ярып алыну, телеп алыну.
**ОТЩИПА'ТЬ** *сов. разг.*— чеметкәләү, чеметкәләп алу.
**ОТЩИПНУ'ТЬ** *сов. разг.*— чеметеп алу.
**ОТЩИ'ПЫВАТЬ** *несов.*— к. отщипнуть, отщипать.
**ОТЩИ'ПЫВАТЬСЯ** *несов. страд.*— чеметкәләп алыну, чеметеп алыну.
**ОТЪЕДА'ТЬ** *несов.*—к. отъесть.
**ОТЪЕДА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. отъесться; 2. *страд.* ашап бетерелү, кимереп бетерелү.
**ОТЪЕ'ЗД** *м. мн.* нет — китү.
**ОТЪЕ'ЗДИТЬ** *сов.*—1. *(кончить ездить)* йөрүдән туктау; 2. *простореч.* күп йөрүдән яраксызлану, тузу, искереп бетү, эштән чыгу; *отъездили мои сани* — минем чанам эштән чыккан.
**ОТЪЕЗЖА'ТЬ** *несов.*— к. отъехать.
**ОТЪЕ'ЗДИТЬСЯ** *сов. простореч.*— барудан туктау, йөрүдән туктау.
**ОТЪЕ'ЗЖИЙ** *спец. устар.*— ерактагы, ерак; *отъезжее поле* — ерактагы басу.
**ОТЪЁМНЫЙ** *разг.* — алынмалы, алына торган, аерып алына торган; *отъёмная крышка* — алынмалы капкач.
**ОТЪЕ'СТЬ** *сов.*— 1. *(кончить есть)* ашап бетерү; *крысы у ней хвост отъели* — күселәр аның койрыгын ашап бетергәннәр; 2. *разг.* тутык ашап төшерү, тутыгудан ашалып төшү (өзелеп); *ржавчиной отъело ручку у чайника* — чәйнек тоткасы тутыгудан ашалып төшкән.
**ОТЪЕ'СТЬСЯ** *сов.*— симерү, көрәю, калынаю, юанаю (яхшы ашап).
**ОТЪЕ'ХАТЬ** *сов.*— 1. *(удалиться на какое-н. расстояние)* китү; 2. *(удалиться в сторону)* читкә китү; 3. *перен. простореч. ирон.* кайтып китү; *он отъехал от него ни с чем* — ул аңардан буш кул белән кайтып китте (бернәрсә ала алмыйча кайтып китте); 4. *перен. разг. фам.* читкә китү, кубу, кубып аерылу, кубып ярык калдыру; *обои отъехали от стены* — обойлар стенадан купканнар; *дверь отъехала сантиметра на три* — ишек өч сантиметр чамасы читкә киткән.
**ОТЪЮ'ЛИВАТЬ** *несов. простореч.* — к. отъюлить.
**ОТЪЮЛИ'ТЬ** *сов. простореч.* — төрле хәйләләр белән котылу, хәйләләп котылу; *ты от этого дела не отъюлишь* — син бу эштән хәйләләп котыла алмассың.
**ОТЪЯВИ'ТЬ** *сов. устар.*— белдерү, таныту.
**ОТЪЯ'ВЛЕННЫЙ** *разг.*— мәгълүм, билгеле, танылган, төзәлә алмаслык, явыз; *отъявленный вор* — танылган карак.
**ОТЪЯВЛЯ'ТЬ** *несов. устар.*— к. отъявить.
**ОТЪЯВЛЯ'ТЬСЯ** *несов. страд. устар.*— танылу, беленү.
**ОТЪЯ'ТЬ** *сов. устар. книж. ритор.* — к. отнять.
**ОТЪЯ'ТЬСЯ** *сов. ритор. устар.* — к. отняться.
**ОТЫГРА'ТЬ** *сов.*— 1. *(играя вернуть)* уйнап кайтару (отылганны); 2. уеннан туктау; *мы уже отыграли* — без уеннан туктадык инде.
**ОТЫГРА'ТЬСЯ** *сов.*— 1. к. отыграть 1; 2. *перен. разг. фам.* хәйләләп, (алдап) кыен хәлдән чыгу, хәйләләп котылу; *отыгрался словами* — төрле сүзләр белән хәйләләп котылды.
**ОТЫ'ГРЫВАТЬ** *несов.*— к. отыграть.
**ОТЫ'ГРЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. отыграться; 2. *страд.* уйнап кайтарылу (отылган нәрсә турында).
**О'ТЫГРЫШ** *м. мн.* нет, *разг.*— 1. *(действие)* к. отыграть; 2. *(отыгранные деньги)* уенда отып кайтарып алынган акча.
**ОТЫМА'ТЬ** *несов. устар. простореч.*— к. отнимать.
**ОТЫМА'ТЬСЯ** *несов. устар. простореч.*— к. отниматься.
**ОТЫМЁННЫЙ** *грам.*— исемнән ясалган; *отымённое наречие* — исемнән ясалган рәвеш.
**ОТЫСКА'ТЬ** *сов.*— эзләп табу.
**ОТЫСКА'ТЬСЯ** *сов. разг.*— эзләп табылу, табылу, килеп чыгу; *отыскался след* — эзе табылды.
**ОТЫ'СКИВАТЬ** *несов.*— к. отыскать.
**ОТЫ'СКИВАТЬСЯ** *несов.*—к. отыскаться.
**ОТЭКЗАМЕНОВА'ТЬ** *сов.*— 1. *(кончить экзаменовать)* имтихан алып бетерү, экзамен алып бетерү; 2. *(кончить экзаменационные испытания)* имтиханнарны тәмамлау.
**ОТЭКЗАМЕНОВА'ТЬСЯ** *сов.* — имтихан биреп бетерү.
**ОТЯГОТЕ'ТЬ** *сов. книж. устар.*— авырлыгы төшү.
**ОТЯГОТИ'ТЬ** *сов. книж.*— авырлык салу, авырлык төшерү, авырлык китерү.
**ОТЯГОТИ'ТЬСЯ** *сов. книж.* — өстенә авырлыклар төшү, өстенә төшү; *отяготился он разными заботами* —аның өстенә төрле мәшәкатьле эшләр төште.
**ОТЯГОЩА'ТЬ** *несов. книж.*— к. отяготить.
**ОТЯГОЩА'ТЬСЯ** *несов. книж.*— 1. к.

отяготиться; 2. *страд.* авырлык салыну, авырлык төшерелү, авырлык китерелү.

**ОТЯГЧА'ТЬ** *несов. книж. устар.*— к. отягчить.

**ОТЯГЧИ'ТЬ** *сов. книж.*— 1. авырайту, авырландыру; 2. к. отяготить.

**ОТЯЖЕЛЕ'ЛЫЙ** *книж.* — авырайган, авыраеп киткән.

**ОТЯЖЕЛЕ'ТЬ** *сов.*—1. авыраю, калынаю, сүлпәнләнү; *голова отяжелела* — баш авырайды; 2. *обл. (забеременеть)* йөккә калу, балага узу, авырга узу.

**ОТЯЖЕЛИ'ТЬ** *сов. книж.*— авырайту.

**ОФЕ'НЯ** *ж. истор.*— кырык тартмачы.

**ОФИЦЕ'Р** *м.*— офицер.

**ОФИЦЕ'РСКИЙ** — офицер...-ы, офицерлар...-ы; *офицерский чин* — офицер чины; *офицерский клуб* — офицерлар клубы.

**ОФИЦЕ'РСТВО** *ср. мн.* нет—1. *собир.* офицерлар; 2. офицерлык дәрәҗәсе; *получить офицерство* — офицерлык дәрәҗәсе алу.

**ОФИЦЕ'РША** *ж. разг. устар.* — офицер хатыны.

**ОФИЦИА'ЛЬНИЧАТЬ** *несов. разг. неодобр.*— артык официаль рәвештә сөйләшү, артык рәсми кылану.

**ОФИЦИА'ЛЬНОСТЬ** *ж.* — 1. *только ед.* рәсмилек; 2. *разг.* рәсми тон, рәсми тонда әйтелгән сүзләр.

**ОФИЦИА'ЛЬНЫЙ** — официаль, рәсми; *официальный документ* — рәсми документ.

**ОФИЦИА'НТ** *м.*, **ОФИЦИА'НТКА** *ж.*— официант (ашханәдә, ресторанда аш китерүче).

**ОФИЦИА'НТСКИЙ** — официант...-ы, официантлык...-ы; *официантские обязанности* — официантлык вазифалары.

**ОФИЦИО'З** *м. книж. полит.*— официоз (капиталистик илләрдә формаль яктан хөкүмәткә бәйләнешле булмаган, ә чынында аны яклый торган, аның фикерен үткәрә торган газета).

**ОФИЦИО'ЗНЫЙ** *книж.* — официоз...; *официозное сообщение* — официоз хәбәр.

**ОФОРМИ'ТЕЛЬ** *м.*— оформитель, бизәүче, матурлаучы (берәр нәрсәне художество ягыннан).

**ОФО'РМИТЬ** *сов.* — 1. оформить итү, рәсмиләштерү; *оформить документ* — документны оформить итү; *оформить стенгазету* — стенгазетаны оформить итү; 2. *перен.* урнаштыру; *оформить кого-н. на работу* — кемне дә булса эшкә урнаштыру.

**ОФО'РМИТЬСЯ** *сов.*— 1. формалашу; *эта мысль оформилась давно* — бу фикер күптән формалашты; 2. *разг.* урнашу; *оформиться на новой работе*—яңа эшкә урнашу.

**ОФОРМЛЕ'НИЕ** *ср.*— 1. *только ед. (действие)* к. оформить; 2. *(внешний вид)* тышкы күренеш. ◇ **Книга с художественным оформлением** — рәсемнәр төшерелгән китап, рәсемле китап.

**ОФО'РМЛИВАТЬ** *несов.*— к. оформить.

**ОФО'РМЛИВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. оформиться; 2. *страд.* формалаштырылу, рәсмиләштерелү, кирәкле форма бирелү, оформить ителү.

**ОФОРМЛЯ'ТЬ** *несов.*— к. оформить.

**ОФОРМЛЯ'ТЬСЯ** *несов.*—1. к. оформиться; 2. *страд.* оформлять ителү.

**ОФО'РТ** *м.*— офорт (металлга кислота ярдәме белән төшерелгән рәсемле гравюра).

**ОФРАНЦУ'ЖИВАТЬ** *несов.*— к. офранцузить.

**ОФРАНЦУ'ЖИВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. офранцузиться; 2. *страд.* французлаштырылу.

**ОФРАНЦУ'ЗИТЬ** *сов.*— французлаштыру.

**ОФРАНЦУ'ЗИТЬСЯ** *сов.*— французлашу.

**ОФСА'ЙД** *м. спорт.*— офсайд (футбол уенында уен кагыйдәләренең берсен бозу).

**ОФСЕ'Т** *м. тип.*— офсет (китап басуның бер ысулы).

**ОФТАЛЬМО'ЛОГ** *м. спец.* — офтальмолог (офтальмология белгече, врач).

**ОФТАЛЬМОЛОГИ'ЧЕСКИЙ** *мед.* — офтальмология...-ы; *офтальмологический кабинет* — офтальмология кабинеты.

**ОФТАЛЬМОЛО'ГИЯ** *ж. мед.* — офтальмология (күз авыруларын өйрәнә торган фән).

**ОХ** *межд.*— ух, ах, әх; *ох, братцы!* — әх, туганнар!

**О'ХАБЕНЬ** *м. истор.*— якалы җилән (боярларның якалы чикмәне, якалы җиләне).

**ОХА'ЖИВАТЬ** *несов. разг. фам.*— к. обхаживать 2, 3.

**ОХА'ИВАТЬ** *несов. простореч.*— к. охаять.

**ОХА'ИВАТЬСЯ** *несов. страд. простореч.* — хурлану, яманлану.

**О'ХАЛА** *м.* и *ж. простореч. фам. неодобр.*—уфылдаучы, сукранучы.

**ОХА'ЛЬНИК** *м. простореч. вульг.*— оятсыз, әдәпсез (кеше).

**ОХА'ЛЬНИЧАТЬ** *несов. простореч. вульг.*— оятсызлану, әдәпсезләнү.

**ОХА'ЛЬНЫЙ** *простореч. вульг.*—оятсыз, әдәпсез.

**О'ХАНЬЕ** *ср. разг.*— уфылдау.

**ОХА'ПКА** *ж. разг.*— кочак, бер кочак; *охапка соломы* — бер кочак салам. ◇ **Взять в охапку** — култык астына кыстырып алу; *шапку в охапку и побежал домой* — бүреген култык астына кыстырды да өенә йөгерде.

**ОХАРАКТЕРИЗОВА'ТЬ** *сов.*— характерлау (рәвешен, сыйфатын сурәтләп, аңлатып бирү); *охарактеризовать, как хвастуна*— мактанчык кеше дип характерлау.

**О'ХАТЬ** *несов.*— уфылдау, ухылдау.

**ОХА'ЯТЬ** *сов. простореч.* — яманлау, хурлау, начар дип табу.

**ОХВА'Т** *м.*— 1. *только ед.* тарту; *стопроцентный охват рабочих завода социалистическим соревнованием* — завод эшчеләренең йөз процентын да социалистик ярышка тарту; 2. *воен.* камау, камап алу, чолгап алу; *охват флангов противника* — дошманның флангларын камап алу.

**ОХВАТИ'ТЬ** *сов.*— 1. кочаклап алу, кочаклау; чолгап алу, урап алу, каплап алу;

*пламя охватило дом* — ялкын өйне каплап алды; 2. урап алу, коршаулап алу; коршау сугу; *охватить бочку железным обручем* — мичкәгә тимер коршау сугу; 3. тарту; *охватить клубной работой массу молодёжи* — яшьләр массасын клуб эшләренә тарту; 4. (*понять, усвоить*) аңлау, башына сыйдыру; 5. *воен.* урап алу, камап алу (дошман гаскәрен); *охватить правый фланг противника* — дошманның уң флангын камап алу. ◇ Охватила радость — бик шатланды, күңеле шатлык белән тулды.

**ОХВА'ТНЫЙ** *спец. воен.* — урап алу...-ы, камап алу...-ы; *охватное движение* — урап алу хәрәкәте.

**ОХВА'ТЫВАТЬ** *несов.* — к. охватить.

**ОХВА'ТЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. чолгап алыну, урап алыну; каплап алыну; камап алыну; 2. тартылу.

**ОХВО'СТЬЕ** *ср. мн.* нет, *собир.* — 1. *с.-х.* койрык, калдык (ашлыкның җилгәргәндә артка, койрыкка төшә торган өлеше); 2. *перен. презрит.* калдык (тар-мар ителгән дошманнар калдыгы).

**ОХЛАДЕВА'ТЬ** *несов. книж.* — к. охладеть.

**ОХЛАДЕ'ЛЫЙ** *книж. поэт.* — 1. суынган; *охладелый труп* — суынган мәет; 2. *перен.* дәртсез; *грустный, охладелый взгляд* — күңелсез, дәртсез караш.

**ОХЛАДЕ'ТЬ** *сов.* — 1. (*стать холодным*) суыну; 2. *перен.* салкын карый башлау, кызыксынмый башлау; *вы охладели к нашему делу* — сез безнең эшкә салкын карый башладыгыз.

**ОХЛАДИ'ТЕЛЬНЫЙ** *хим.* — суыта торган.

**ОХЛАДИ'ТЬ** *сов. книж.* — 1. суыту, салкынайту; *охладить вскипячённую воду* — кайнатылган суны суыту; 2. *перен.* (*сделать равнодушным*) күңелен кайтару, дәртен сүндерү.

**ОХЛАДИ'ТЬСЯ** *сов. книж.* — 1. (*стать холодным*) суыну, салкынаю; 2. *перен.* (*стать более сдержанным в чувствах*) күңел кайту, күңел суыну, кызыксынмый башлау, салкын карый башлау, дәрте сүнү.

**ОХЛАЖДА'ТЬ** *несов. книж.* — к. охладить.

**ОХЛАЖДА'ТЬСЯ** *несов. книж.* — 1. к. охладиться; 2. *страд.* суытылу, салкынайтылу; күңел кайтарылу, дәрте сүндерелү.

**ОХЛО'ПАТЬ** *сов. устар.* — кул чабып каршы алу.

**ОХЛО'ПОК** *м.* — 1. бер тотам, бер учма; *охлопок шерсти* — бер учма йон; 2. *только ед. собир. спец.* калдык; *льняной охлопок* — җитен калдыгы.

**ОХЛО'ПЬЕ** *ср. собир. мн.* нет, *спец.* — к. охлопок 2.

**ОХМЕЛЕ'ТЬ** *сов. разг.* — исерү.

**ОХМЕЛИ'ТЬ** *сов.* — 1. *обл.* исертү; 2. *перен.* дулкынландыру, дәртләндерү.

**ОХМЕЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. охмелить.

**О'ХНУТЬ** *сов. разг. однокр.* — уфылдап кую.

**ОХОЛОДЕ'ТЬ** *сов. редко* — к. охладеть.

**ОХОЛОДИ'ТЬ** *сов. редко* — к. охладить.

**ОХОЛОСТИ'ТЬ** *сов. спец.* — печү, печтерү (хайванны); *охолостить жеребца* — айгырны печтерү.

**ОХОРА'ШИВАТЬ** *несов. разг.* — купшыландыру, матурландыру, ыспайландыру; *охорашивать ребёнка* — баланы ыспайландыру.

**ОХОРА'ШИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — купшылану, матурлану, ыспайлану.

**ОХО'ТА** *ж. мн.* нет — 1. ау, аучылык, сунарчылык; 2. *разг.* теләк, һәвәс, дәрт; *большая у него охота к учению* — аның укырга дәрте зур. ◇ Охота поесть *простореч.* — ашыйсы килә. Охота тебе — нигә кирәк ул сиңа, нәрсәгә ул сиңа. В охоту *простореч.* — зур теләк белән, бик рәхәтләнеп.

**ОХО'ТИТЬСЯ** *несов.* — 1. сунарчылык итү, аучылык итү, аулау; 2. *перен. разг.* алырга тырышып йөрү; *он охотится за этой книгой* — ул бу китапны алырга тырышып йөри; 3. *простореч. ирон.* чамалап йөрү, теләү, дәртләнеп йөрү; *он всё охотится к вам в гости прийти* — ул һаман сезгә кунакка барырга дәртләнеп йөри.

**ОХО'ТКА** *ж. мн.* нет, *разг. простореч. уменьш.* — к. охота. ◇ В охотку *разг. фам.* — тансыкка, бик рәхәтләнеп, зур теләк белән.

**ОХО'ТНИК** *м.* — 1. сунарчы, аучы; 2. теләүче; *вызвать охотников на разведку* — разведкага барырга теләүчеләрне чакырып алу; 3. һәвәскәр кеше, ярата торган кеше, ...-га яратучан кеше; *охотник посплетничать* — гайбәт сатарга яратучан кеше.

**ОХО'ТНИЦА** *ж.* — к. охотник 3.

**ОХО'ТНИЧИЙ** — 1. ау...-ы, аучылар...-ы; *охотничья собака* — ау эте; *охотничьи организации* — аучылар оешмалары; 2. *шутл. ирон.* ялган; *охотничьи рассказы* — ялган сүзләр, ялган хикәяләр.

**ОХО'ТНО** *нареч.* — зур теләк белән, бик теләп; *он охотно согласился* — ул бик теләп риза булды.

**ОХОТОВЕ'Д** *м. спец.* — аучылык белгече, сунарчылык белгече.

**ОХОТОВЕ'ДЕНИЕ** *ср. мн.* нет, *спец.* — аучылык белеме.

**ОХО'ЧИЙ** *обл.* — теләүчән, яратучан, бик һәвәс; *охочий по магазинам бегать* — магазиннарга йөрергә яратучан кеше.

**О'ХРА** *ж. мн.* нет — охра (сары яки кызыл төстәге минераль буяу).

**ОХРА'НА** *ж. мн.* нет — 1. (*действие*) к. охранять; 2. сакчылар, сакчылар отряды; *помещение для охраны* — сакчылар бинасы. ◇ Охрана труда — хезмәтне саклау.

**ОХРАНЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — 1. *книж.* (*действие*) к. охранять; 2. *воен.* сакчылар отряды.

**ОХРАНИ'ТЕЛЬ** *м. книж.* — 1. *ритор.* саклаучы, яклаучы; *охранитель нравственности* — әхлаклылык саклаучы; 2. *доревол. публиц.* консерватор, реакционер.

**ОХРАНИ'ТЕЛЬНЫЙ** — 1. *спец. право* саклау...-ы, саклау хезмәтен үти торган; *охранительное право* — саклау хокукы; 2. *до-*

*револ.* консерватив; реакцион; *охранительное направление* — реакцион юнәлеш.

**ОХРАНИ'ТЬ** *сов.* — саклап алып калу.

**ОХРА'НКА** *ж. разг.* — охранка (патша Россиясендә һәм буржуаз илләрдә яшерен полиция).

**ОХРА'ННИК** *м. разг.* — 1. каравылчы, сторож; 2. *дореvол.* охранка агенты, шпион (патша Россиясендә һәм буржуаз илләрдә).

**ОХРА'ННЫЙ** *книж. офиц.* — саклана торган, саклый торган; *охранная зона* — саклана торган зона. ◇ **Охранная грамота** — охранный грамота (берәр кешенең яки аның милкенең хөкүмәт органнары тарафыннан саклануы турында бирелгән документ). **Охранное отделение** — к. охранка.

**ОХРАНЯ'ТЬ** *несов.* — саклау, каравыллау.

**ОХРАНЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — саклану, каравыллану.

**ОХРИ'ПЛЫЙ** — карлыккан; *охриплый голос* — карлыккан тавыш.

**ОХРИ'ПНУТЬ** *сов.* — тамак карлыгу, карлыгу.

**О'ХРИПЬ** *ж. мн.* нет, *разг.* — тавыш бетү.

**О'ХРИТЬ** *несов. спец.* — охра белән буяу.

**ОХРОМЕ'ТЬ** *сов. разг.* — аксаклану, чатанлану, чатанлый башлау, аксый башлау.

**ОХРЯ'НКА** *ж. спец.* — охралы балчык.

**ОХУЖДА'ТЬ** *несов. устар.* — әшәке дип тану, хурлау, начар дип табу.

**ОХУЛИ'ТЬ** *сов. устар. простореч.* — хурлау, яманлау, яман атын сату.

**ОХУ'ЛКА** *ж. разг. фам.*: **охулки на руку не класть** — бармагы үзенә таба кәкре.

**ОЦАРА'ПАТЬ** *сов.* — тырнау, тырнап алу; *кошка меня оцарапала* — мине песи тырнады.

**ОЦАРА'ПАТЬСЯ** *сов.* — тырналу, тырналып бетү, сыдырылып бетү.

**ОЦАРА'ПНУТЬ** *сов. разг. однокр.* — к. оцарапать.

**ОЦЕДИ'ТЬ** *сов. устар.* — 1. к. отцедить 2; 2. (*процедить*) сөзеп алу, сөзеп чистарту (мәсәлән, сөтне).

**ОЦЕ'ЖИВАТЬ** *несов. устар.* — к. оцедить.

**ОЦЕ'ЖИВАТЬСЯ** *несов. страд. устар.* — сөзелү, сөзеп алыну.

**ОЦЕЛО'Т** *м.* — оцелот (Урта Америкада яши торган зур кыргый мәче).

**ОЦЕ'НИВАТЬ** *несов.* — к. оценить.

**ОЦЕ'НИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. (*рассматриваться*) каралу, бәя бирелү; 2. *страд.* хак бирелү, бәя куелу, хакы билгеләнү, бәя бирелү.

**ОЦЕНИ'ТЬ** *сов.* — 1. (*определить стоимость*) хак бирү, бәя кую, хакын билгеләү; 2. бәяләү, бәя бирү; *правильно оценить создавшееся положение* — килеп чыккан хәлгә дөрес бәя бирү; *оценить по достоинству* — тиешле бәя бирү, лаеклы бәя бирү, кадерен белү.

**ОЦЕ'НКА** *ж.* — 1. *только ед.* (*действие*) к. оценить; 2. бәя, хак, билге.

**ОЦЕ'НОЧНЫЙ** — 1. куелган, билгеләнгән; *оценочная стоимость* — куелган хак; 2. хаклар билгели торган, хак куя торган; *оценочная комиссия* — хаклар билгели торган комиссия.

**ОЦЕ'НЩИК** *м. спец.* — хак куючы, хаклар билгеләүче.

**ОЦЕПЕНЕ'ЛЫЙ** — катып калган; *оцепенелый вид* — катып калган кыяфәт.

**ОЦЕПЕНЕ'ТЬ** *сов.* — катып калу, шашып калу; *оцепенеть от страха* — куркудан катып калу, шашып калу.

**ОЦЕПИ'ТЬ** *сов.* — камап алу, уратып алу; *войска оцепили город* — гаскәрләр шәһәрне камап алдылар.

**ОЦЕПЛЕ'НИЕ** *ср.* — 1. *только ед.* (*действие*) к. оцепить; 2. *спец.* камап ала торган гаскәр.

**ОЦЕПЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. оцепить.

**ОЦЕПЛЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — камап алыну, уратып алыну.

**О'ЦЕТ** *м. устар. ритор.* — серкә, уксус.

**ОЦИНКОВА'ТЬ** *сов. спец.* — цинклау, цинк белән каплау, цинк йөгертү; *оцинковать ведро* — чиләкне цинклау.

**ОЦИНКО'ВОЧНЫЙ** *спец.* — цинклау...-ы, цинк йөгертү...-ы; *оцинковочный цех* — цинклау цехы.

**ОЦИНКО'ВЩИК** *м. спец.* — цинклаучы, цинк йөгертүче эшче.

**ОЦИНКО'ВЫВАТЬ** *несов. спец.* — к. оцинковать.

**ОЦИНКО'ВЫВАТЬСЯ** *несов. страд. спец.* — цинклану, цинк белән каплану, цинк йөгертелү.

**ОЧА'Г** *м.* — 1. учак; 2. *перен.* учак, чыккан урын, чыганак; *очаг заразы* — йогышлы авырулар чыганагы; *очаг пожара* — янгын чыккан урын; *культурный очаг* — культура учагы; *потушить очаги войны* — сугыш учакларын сүндерү. ◇ **Домашний очаг** *ритор.* — семья, өй.

**ОЧАГО'ВЫЙ** *спец.* — учак...-ы; *очаговое углубление* — учак чокыры.

**ОЧА'НКА** *ж. бот.* — күз уты, күз үләне (чүп үлән).

**ОЧАРОВА'НИЕ** *ср. мн.* нет — к. очаровать.

**ОЧАРО'ВАННО** *нареч.* — сокланып, исе китеп; *глядеть очарованно* — сокланып карап тору.

**ОЧАРОВА'ТЕЛЬНЫЙ** — сокландыргыч, бик яхшы; *очаровательный ребёнок* — сокландыргыч бала.

**ОЧАРОВА'ТЬ** *сов.* — сокландыру, хәйран калдыру, сөйдерү, гашыйк итү.

**ОЧАРОВА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — соклану, гашыйк булу.

**ОЧАРО'ВЫВАТЬ** *несов.* — к. очаровать.

**ОЧАРО'ВЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. очароваться; 2. *страд.* сокландырылу, сөйдерелү.

**ОЧЕВИ'ДЕЦ** *м.*, **ОЧЕВИ'ДИЦА** *ж.* — үз күзе белән күрүче, шаһит.

**ОЧЕВИ'ДНО** *ввод. сл.* — мөгаен, күрәсең; *очевидно, он уже не придет* — ул, күрәсең, килмәс инде.

**ОЧЕВИ'ДНЫЙ** — 1. (*бесспорный, явный*) ачык, ап-ачык, күренеп тора торган, һич-

шиксез; 2. үз күзе белән күргән; *очевидные свидетели* — үз күзе белән күргән шаһитлар.

**ОЧЕЛОВЕ'ЧЕНИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — кешегә әйләнү, кешегә әверелү.

**ОЧЕЛОВЕ'ЧИВАТЬ** *несов. книж.* — кешеләштерү, кешегә әверелдерү.

**ОЧЕЛОВЕ'ЧИВАТЬСЯ** *несов. книж.* — к. очеловечиться.

**ОЧЕЛОВЕ'ЧИТЬ** *сов. книж.* — к. очеловечивать.

**ОЧЕЛОВЕ'ЧИТЬСЯ** *сов. книж.* — кешеләшү, кешегә охшау.

**О'ЧЕННО** *нареч. простореч. обл.* — к. очень.

**О'ЧЕНЬ** *нареч.* — бик; *очень холодно* — бик салкын.

**ОЧЕРВИ'ВЕТЬ** *сов.* — кортлау, кортлап бетү.

**ОЧЕРЕДНО'Й** — 1. алда торган, иң якындагы; *очередная задача* — алда торган бурыч; 2. чираттагы; *очередная смена рабочих* — эшчеләрнең чираттагы сменасы; 3. гадәттәге; *очередная выходка шалуна* — шаянның гадәттәге кыланышы.

**ОЧЕРЁДНОСТЬ** *ж. мн.* нет — чиратлылык, чират; *установить очерёдность* — чират кую.

**О'ЧЕРЕДЬ** *ж.* — чират, нәүбәт. ◇ **Пулемётная очередь** — пулемёт очереды. **В первую очередь** — иң әлек, иң башта, беренче чиратта. **В свою очередь** — башкалар шикелле, үз нәүбәтендә, үз чиратында.

**ОЧЕРЕ'Т** *м. обл.* — камыш, камышсыман үсемлекләр.

**ОЧЕРЕ'ТОВЫЙ** *обл.* — камыш ..., камыштан ясалган; *очеретовая крыша* — камыш түбә.

**О'ЧЕРК** *м. книж.* — очерк (әдәби яки гыйльми әсәр); *очерки по русской истории* — рус (халкы) тарихы буенча очерклар.

**ОЧЕРКИ'СТ** *м.*, **ОЧЕРКИ'СТКА** *ж.* — очеркист, очерклар язучы.

**ОЧЕРКИ'СТСКИЙ** — очерк...ы, очерклар...ы; *очеркистский стиль* — очерклар стиле.

**ОЧЕРКНУ'ТЬ** *сов.* — түгәрәкләп сызып алу.

**ОЧЕРНИ'ТЬ** *сов.* — кара ягу, яла ягу, яман атын чыгару.

**ОЧЕРНЯ'ТЬ** *несов.* — к. очернить.

**ОЧЕРСТВЕ'ЛЫЙ** — тупас, каты, түң, рәхимсез; *очерствелое сердце* — түң йөрәк, рәхимсез йөрәк.

**ОЧЕРСТВЕ'ТЬ** *сов.* — күңел каты, күңел тупаслану, рәхимсезләнү.

**ОЧЕРСТВИ'ТЬ** *сов.* — тупасландыру, шәфкатьсезләндерү, күңелен катыру.

**ОЧЕРСТВИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — к. очерстветь.

**ОЧЕРСТВЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. очерствить.

**ОЧЕРТА'НИЕ** *ср.* — сызык; *вдали видны очертания гор* — еракта тау сызыклары күренә.

**ОЧЕРТЕ'ТЬ** *сов. простореч.* — туйдырып бетерү, теңкәгә тиеп бетү.

**ОЧЕРТИ'ТЬ** *сов.* — 1. түгәрәкләп сызып алу; *очертить рисунок* — сурәтне түгәрәкләп сызып алу; 2. *книж.* гомуми рәвештә сөйләп бирү, язып бирү; *очертить создавшееся положение* — килеп чыккан хәлне гомуми рәвештә сөйләп бирү. ◇ **Очертя голову** *разг.* — уйламый-нитми, уңын-сулын карамыйча.

**ОЧЕ'РЧИВАТЬ** *несов.* — к. очертить.

**ОЧЕ'РЧИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. түгәрәкләп сызып алыну; 2. гомуми рәвештә сөйләп бирелү, гомуми рәвештә язып бирелү.

**ОЧЁС** *м. мн.* нет, *собир. спец.* — к. очёски.

**ОЧЕСА'ТЬ** *сов. спец.* — к. обчесать 1.

**ОЧЁСКИ** *мн. спец.* — тарак асты, чүбек (сүс тараганнан соң калган калдыклар); *очёски льна* — җитен чүбеге.

**ОЧЁСЫВАТЬ** *несов. спец.* — к. очесать.

**ОЧЁСЫВАТЬСЯ** *несов. страд. спец.* — тарап тазартылу.

**ОЧЕ'ЧНИК** *м. разг. устар.* — күзлек савыты.

**ОЧЕ'ЧНЫЙ** *разг. устар.* — күзлек ...-ы; *очечное стекло* — күзлек пыяласы.

**ОЧИ'НИВАТЬ** *несов. разг.* — к. очинить.

**ОЧИ'НИВАТЬСЯ** *несов. страд. разг.* — очлану.

**ОЧИНИ'ТЬ** *сов.* — очлау (юнып очлау); *очинить карандаш* — карандаш очлау.

**ОЧИНЯ'ТЬ** *несов.* — к. очинить.

**ОЧИНЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — к. очиниваться.

**ОЧИСТИ'ТЕЛЬ** *м. спец.* — тазарткыч, чистарткыч (прибор).

**ОЧИСТИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.* — 1. тазарта торган, тазарту ...-ы; *очистительный прибор* — тазарту приборы; 2. *устар.* гөнаһларны кичерә торган, йола торган, сафландыра торган; *очистительная жертва* — гөнаһларны кичерә торган корбан.

**ОЧИ'СТИТЬ** *сов.* — 1. чистарту, тазарту; *очистить дно реки* — елганың төбен тазарту; 2. әрчү, арчу; *очистить картошку* — бәрәңге арчу; 3. бушату; *очистить зал* — залны бушату; 4. чыгып китү; *жильцы очистили помещение* — торучылар бинадан чыгып киттеләр; 5. *перен. фам.* талау, урлап чыгып китү, урлап чыгу. ◇ **Очистить совесть признанием** — дөресен әйтеп вөҗданны тынычландыру.

**ОЧИ'СТИТЬСЯ** *сов.* — 1. тазару, чистару; 2. арчылу; *река очистилась от льда* — елга боздан арчылды; 3. (*опорожниться*) бушау.

**ОЧИ'СТКА** *ж. мн.* нет, *спец.* — к. очистить 1, 2, 3, 4. ◇ **Для очистки совести** *разг.* — күңел тынычлыгы өчен, вөҗдан тынычлыгы өчен.

**ОЧИ'СТКИ** *ед.* нет, *спец.* — калдыклар (тазартканнан соң калган). ◇ **Картофельные очистки** — бәрәңге кабыклары.

**ОЧИ'СТНЫЙ** *спец.* — тазарту ...-ы; *очистные сооружения* — тазарту корылмалары.

**ОЧИ'ТОК** *м. бот.*— кәрләч; сәхрә борычы, дию борычы.

**ОЧИЩА'ТЬ** *несов.*— к. очистить.

**ОЧИЩА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. очиститься; 2. *страд.* тазартылу, чистартылу.

**ОЧКА'СТЫЙ** *простореч.*— күзлекле, күзлек кигән; *очкастый человек* — күзлекле кеше.

**ОЧКИ'** *ед.* нет — күзлек. ◇ **Он смотрит на жизнь сквозь розовые очки** — тормышка ул ал күзлек аша карый (тормышның ул яхшы ягын гына күрә).

**ОЧКО'** *ср.*— 1. сан билгесе (карта уенында, доминода); 2. *спорт.* очко (сан бирәмлеге); 3. кечкенә тишек (берәр нәрсәдә); 4. *с.-х.* күз (бәрәңгедә); бөре (үсемлектә); 5. *тип.* кабарынкы хәреф. ◇ **Втереть очки** *разг.*— күз буяу.

**ОЧКОВА'ТЬ** *несов. сад.*— бөре белән ялгау.

**ОЧКОВТИРА'ТЕЛЬ** *м. неодобр.*— күз буяучы.

**ОЧКОВТИРА'ТЕЛЬСТВО** *ср. мн.* нет, *неодобр.*— күз буяу.

**ОЧКО'ВЫЙ** *зоол.*: очковая змея — күзлекле елан.

**ОЧКУ'Р** *м. обл.*— ычкыр (ыштан бавы).

**ОЧНУ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. (*проснуться*) уяну, уянып китү; 2. (*прийти в чувство, в сознание*) һушка килү, искә килү, аңга килү.

**О'ЧНЫЙ**: очная ставка *офиц.*— күзгә-күз, кара-каршы китереп сорау алу; очное обучение — уку йортына йөреп уку.

**ОЧУ'ВСТВОВАТЬСЯ** *сов.*— 1. *устар.* к. очнуться 2; 2. *разг.* хатасын аңлау, үкенү; *он очувствовался, но было уже поздно* — ул хатасын аңлады, ләкин соң иде инде.

**ОЧУМЕ'ЛЫЙ** *простореч.*— котырган, тилергән, шашкан; *бежит, как очумелый* — котырган кебек йөгерә.

**ОЧУМЕ'ТЬ** *сов. простореч.*— котыру, тилерү, шашу.

**ОЧУТИ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. барып чыгу, килеп чыгу (уйламаган нигдидер берәр хәлгә яки урынга); *очутился на краю города* — шәһәр читенә барып чыккан; 2. калу, төшү; *очутиться в трудном положении* — авыр хәлгә төшү.

**ОЧУ'ХАТЬСЯ** *сов. простореч.*— к. очнуться 2.

**ОШАЛЕВА'ТЬ** *несов. простореч.*— к. ошалеть.

**ОШАЛЕ'ЛЫЙ** *простореч.*— шашкан, тилергән, акылдан язган; *от радости ходит, как ошалелый* — шатлыгыннан акылдан язгандай йөри.

**ОШАЛЕ'ТЬ** *сов. простореч.*— шашу акылдан язу.

**ОШАРА'ШИТЬ** *сов. простореч.*— 1. бик каты сугу; 2. (*озадачить, поставить в тупик*) уйга калдыру, шаккатыру, хәйран калдыру, аптырашта калдыру.

**ОШВАРТОВА'ТЬ** *сов. мор.*— бәйләп кую (пароходны причалга).

**ОШВАРТОВА'ТЬСЯ** *сов. мор.*— причалга туктау.

**ОШВАРТО'ВИТЬ** *сов. мор.*— к. ошвартовать.

**ОШЕ'ЕК** *м. спец.*— муен ите.

**ОШЕ'ЙНИК** *м.*— муенчак.

**ОШЕЛОМИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.*— шаккатыргыч, шаккатырырлык, һуштан яздырырлык; *ошеломительное известие* — шаккатыргыч хәбәр.

**ОШЕЛОМИ'ТЬ** *сов.*— шаккатыру, хәйран калдыру, ис китәрү, аптырашта калдыру; *он ошеломил меня своим вопросом* — ул үзенең соравы белән мине аптырашта калдырды.

**ОШЕЛОМЛЯ'ТЬ** *несов.*— к. ошеломить.

**ОШЕЛУДИ'ВЕТЬ** *сов. простореч.* — корчаңгыланып бетү, корчаңгы басу, тазланып бетү.

**ОШЕЛЬМОВА'ТЬ** *сов. разг.*— әдәм актыгы итеп күрсәтү, явыз дип хурлау.

**ОШЕПЕЛЯ'ВЕТЬ** *сов. простореч.* — сакаулану, сакауланып сөйли башлау.

**ОШИБА'ТЬСЯ** *несов.*— к. ошибиться.

**ОШИБИ'ТЬСЯ** *сов.*— хата җибәрү, ялгышу.

**ОШИ'БКА** *ж.*— ялгыш, хата, ялгышлык.

**ОШИ'БОЧНЫЙ** *книж.*— ялгыш, ялгышлык белән эшләнгән; *ошибочное решение* — ялгыш карар.

**ОШИ'КАТЬ** *сов. разг.*— пышылдап (сызгырып) канәгатьсезлек белдерү, ризасызлык белдерү (мәсәлән, театрда).

**ОШКОЛЯ'РИТЬ** *сов. разг. устар.*— педантлаштыру, схоластиклаштыру.

**ОШЛАКОВА'ТЬ** *сов. тех.*— шлакка әверелдерү.

**ОШМЁТКИ** *мн. простореч.*—1. тапталып беткән иске итек (чабата); 2. өзгәләнеп беткән кисәкләр; *от папки остались одни ошмётки* — папкадан өзгәләнеп беткән кисәкләр генә калган.

**ОШПА'РИВАТЬ** *несов. разг.*— к. ошпарить.

**ОШПА'РИВАТЬСЯ** *несов. разг.*— к. ошпариться.

**ОШПА'РИТЬ** *сов. разг.*— 1. пешекләү, парлау (кайнар су белән); 2. пешерү (кайнар су түгеп, сибеп); *ошпарил руку* — кулымны кайнар суга пешердем.

**ОШПА'РИТЬСЯ** *сов. разг.*— пешү.

**ОШТРАФОВА'ТЬ** *сов.*— штраф салу, штраф түләтү.

**ОШТУКАТУ'РИТЬ** *сов.*— штукатурлау.

**ОШУ'ЮЮ** *нареч. книж. старин.*— сул якта.

**ОЩЕНИ'ТЬ** *сов. простореч.*— балалау (эт турында).

**ОЩЕНИ'ТЬСЯ** *сов.*— к. ощенить.

**ОЩЕ'РИВАТЬ** *несов. разг.*— к. ощерить.

**ОЩЕ'РИВАТЬСЯ** *несов. разг.*— 1. к. ощериться: 2. *страд.* ыржайтылу.

**ОЩЕ'РИТЬ** *сов. разг.*— ыржайту; *ощерить зубы* — тешләрен ыржайту.

**ОЩЕ'РИТЬСЯ** *сов. разг.*— ыржаю, тешләрне ыржайту.

**ОЩЕТИ'НИВАТЬ** *несов. разг.*— к. ощетинить.

**ОЩЕТИ'НИВАТЬСЯ** *несов. разг.*— к. ощетиниться.

**ОЩЕТИ'НИТЬ** *сов. разг.*— сырт йонын кабарту, сыртын кабарту.

**ОЩЕТИ'НИТЬСЯ** *сов. разг.*— 1. к. ощетинить; 2. *перен. разг.* ачу килү.

**ОЩИ'ПАННЫЙ** — 1. йолкынган; 2. *перен. разг. фам.* бичара, мескен; *ощипанный вид* —мескен кыяфәт.

**ОЩИПА'ТЬ** *сов. разг.*— йолкып бетерү.

**ОЩИПА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — йолкынып бетү.

**ОЩИ'ПЫВАТЬ** *несов.*— к. ощипать.

**ОЩИ'ПЫВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. ощипаться; 2. *страд.* йолкып бетерелү.

**ОЩУ'ПАТЬ** *сов.*— капшау, кармалау, капшап чыгу, кармалап чыгу; *ощупать карманы* — кесәләрне капшау.

**ОЩУ'ПАТЬСЯ** *сов. разг.*— үзенне тирәли капшап чыгу, кармалап чыгу.

**ОЩУ'ПЫВАТЬ** *несов.*— к. ощупать.

**ОЩУ'ПЫВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. ощупаться; 2. *страд.* капшап чыгылу, кармалап чыгылу.

**О'ЩУПЬ** *ж.:* **на ощупь** — капшап карауга, кармалап карауга.

**О'ЩУПЬЮ** *нареч.*— кармалый-кармалый, капшана-капшана.

**ОЩУТИ'МОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— сизелерлек булу, беленерлек булу.

**ОЩУТИ'МЫЙ** *книж.* — сизелерлек, беленерлек; *холод здесь мало ощутим* — суык монда артык сизелерлек түгел.

**ОЩУТИ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— к. ощутимость.

**ОЩУТИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.*— сизелерлек, беленерлек; *ощутительные успехи* — сизелерлек уңышлар.

**ОЩУТИ'ТЬ** *сов. книж.* — сизү, тою; *ощутить холод* — суыкны сизү.

**ОЩУЩА'ТЬ** *несов. книж.* — к. ощутить.

**ОЩУЩА'ТЬСЯ** *несов. страд. книж.*— сизелү, тоелу; *ощущается потребность отдохнуть* — ял итү кирәклеге сизелә.

**ОЩУЩЕ'НИЕ** *ср. книж.*— 1. *только ед.* (*действие*) к. ощущать; 2. (*псих. физиол.*) сизү, тою, тойгы; 3. (*переживание*) кичерү, баштан үткәрү.

**ОЯГНИ'ТЬСЯ** *сов.*— бәрәнләү.

**ОЯ'ЛОВЕТЬ** *сов. обл.*— кысыр калу (сыер турында).

---

## ТӨЗӘТМӘЛӘР

| бит | юл | басылган | укырга |
|---|---|---|---|
| 10 | 3 | ИЗГОРБИ'ТЬ | ИЗГО'РБИТЬ |
| 10 | 5 | ИЗГОРБИ'ТЬСЯ | ИЗГО'РБИТЬСЯ |
| 15 | 47 | китерү | китәрү |
| 16 | 25 | ИЗМЯ'КАТЬ | ИЗМЯКА'ТЬ |
| 53 | 42 | КАЙРА' | КА'ЙРА |
| 71 | 27 | *квасная* | *квасной* |
| 72 | 46 | КВО'ХТАТЬ | КВОХТА'ТЬ |
| 72 | 50 | КЕ'ГЕЛЬБАН | КЕГЕЛЬБА'Н |
| 72 | 5 | КЕЛА'РЬ | КЕ'ЛАРЬ |
| 76 | 49 | КИ'ЧИТЬСЯ | КИЧИ'ТЬСЯ |
| 76 | 22 | КЛАВИАТУ'РА *м.* | КЛАВИАТУ'РА *ж.* |
| 80 | 36 | КЛИ'СТИР | КЛИСТИ'Р |
| 83 | 25 | КОБЫ'ЛИЦА | КОБЫЛИ'ЦА |
| 101 | 54 | КОНТРА ГЕНТ | КОНТРАГЕ'НТ |
| 116 | 14 | КРАСЯ'ЩИЙ | КРА'СЯЩИЙ |
| 116 | 56 | КРАШЕ'НИЕ | КРА'ШЕНИЕ |
| 117 | 46 | КРЕЙСИРОВА'ТЬ | КРЕЙСИ'РОВАТЬ |
| 122 | 18 | КРО'ПАТЬ | КРОПА'ТЬ |
| 128 | 14 | КУЛИНАРИ'Я | КУЛИНА'РИЯ |
| 130 | 27 | КУ'РЕНЬ | КУРЕ'НЬ |
| 139 | 53 | ЛАТИНЯ'НИН | ЛАТИ'НЯНИН |
| 146 | 46 | ЛЕССИ'РОВАТЬ | ЛЕССИРОВА'ТЬ |
| 146 | 50 | ЛЕССИ'РОВАТЬСЯ | ЛЕССИРОВА'ТЬСЯ |
| 147 | 33 | ЛЕ'ТОШНЫЙ | ЛЕ'ТОШНИЙ |
| 149 | 65 | сызык(лар) ...-ы | сызгыч(лар) ...-ы |
| 151 | 33 | ЛИСОВЩИ'К | ЛИСО'ВЩИК |
| 157 | 30 | ЛО'МОТЬ | ЛОМО'ТЬ |
| 157 | 49 | *лопарьский* | *лопарский* |
| 190 | 19 | МЕРЯ'ЛЬЩИК | МЕ'РЯЛЬЩИК |
| 190 | 19 | МЕРЯ'ЛЬЩИЦА | МЕ'РЯЛЬЩИЦА |
| 190 | 21 | МЕРЯ'ТЬ | МЕ'РЯТЬ |
| 225 | 7 | чыгарту | чыгару |
| 240 | 9 | НАЖИ'МАТЬСЯ | НАЖИМА'ТЬСЯ |
| 306 | 45 | НЕДУОБОЧИТА'ЕМЫЙ | НЕУДОБОЧИТА'ЕМЫЙ |
| 345 | 29 | КИРЕ | БАРУ ҺӘМ |
| 332 | 66 | ЧАТЬ | ОБЛАЧАТЬ |

Издательство редакторлары: *Х. Н. Мөхәметшин, Ф. Х. Хәсәнов, А. Г. Әхмәдуллин*

Техник редакторы *М. Җ. Шәрәфетдинова*

О Корректорлары: *Ә. Г. Идрисова, З. И. Шагдалеева*

---

Наборга бирелде 22/II-1956 ел. Басарга кул куелды 10/V-1956 ел. ПФ 00061. Кәгазь форматы $70 \times 108^{1}/_{16}$.
Учет-изд. 59,57 таб. Басма табак 28,75 (39,39). Табакта 68100 хәреф.
Заказ № 087. Тираж 35000. Бәясе 12 сум 25 тиен.

---

ТАССР Культура Министрлыгының Татполиграф типографиясе.
Казан, Миславский ур., йорт № 9.

АКАДЕМИЯ НАУК СССР
КАЗАНСКИЙ ФИЛИАЛ
ИНСТИТУТ ЯЗЫКА, ЛИТЕРАТУРЫ И ИСТОРИИ

# РУССКО-ТАТАРСКИЙ СЛОВАРЬ

ТОМ
2

## И-О

ТАТКНИГОИЗДАТ
РЕДАКЦИЯ НАУЧНО-ТЕХНИЧЕСКОЙ ЛИТЕРАТУРЫ
Казань 1956

СССР ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
КАЗАН ФИЛИАЛЫ
ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ ТАРИХ ИНСТИТУТЫ

# РУСЧА-ТАТАРЧА СҮЗЛЕК

ТОМ
2

## И-О

ТАТКНИГОИЗДАТ
ФӘННИ-ТЕХНИК ӘДӘБИЯТ РЕДАКЦИЯСЕ
Казан 1956

В составлении словаря принимали участие:

*Р. С. Газизов* (буквы И, К, М),
*Л. Т. Махмутова* (буквы Л, Н),
*Э. М. Ахунзянов* (букву О).

В составлении статей словаря на буквы И, М принимала также участие *Ф. М. Газизова*.

Редакционная коллегия:

*Р. С. Газизов, М. Максуд, Ф. Г. Исхаков.*

## ОТ СОСТАВИТЕЛЕЙ

При составлении словаря основное внимание было обращено на более точную передачу значений русских слов на татарский язык. При этом особо серьезное внимание обращалось на то, чтобы грамматическое оформление татарских слов, приводимых в качестве эквивалентов к русским словам, давало бы возможность употребить их в связной речи в любом предложении.

Наибольшую трудность в этом отношении представляет передача русских относительных и притяжательных прилагательных, так как они на татарский язык могут быть переведены различными способами.

Во-первых, некоторые из них могут быть переданы при помощи специальных суффиксов *-лы, -ле, -лык, -лек, -гы, -ге* и др., которые в татарском языке являются формальным показателем относительности имён прилагательных. Например, *летний* — җәйге; *летнее платье* — җәйге күлмәк; *солнечный* — кояшлы; *солнечный день* — кояшлы көн. Во-вторых, в тех случаях, когда русские относительные и притяжательные прилагательные в татарском языке не могут быть выражены каким-нибудь формальным показателем, их значение передается исходной формой имени существительного, которое, находясь в определенном контексте, может выполнять функцию относительного прилагательного. Например, выражение *каменный дом* на татарский язык может быть переведено как *таш өй*, где слово *таш* соответствует русскому слову *каменный*, а слово *өй* соответствует слову *дом*.

Таким образом, здесь русскому отымённому прилагательному *каменный* в татарском языке соответствует исходная форма имени существительного *таш*, употреблённая в данном случае в функции прилагательного. Но учитывая то, что исходная форма имени существительного, взятая вне контекста, в татарском языке никогда не может выполнять функцию прилагательного (напр., слово *таш* вне контекста означает только *камень*, но не имеет значения прилагательного *каменный*), в настоящем словаре, как и в некоторых других русско-тюркских словарях, для указания того, что имя существительное в данном случае выполняет функцию имени прилагательного, ставится после него многоточие, которое показывает, что дальше следует определяемое им существительное. Например, *каменный* — таш...; *каменный дом* — таш өй; *деревянный* — агач...; *де-*

*ревянный дом* — агач өй; *стеклянный* — пыяла...; *стеклянный стакан* — пыяла стакан и т. д.

Если же определяемое существительное принимает аффикс принадлежности 3-го лица ***-ы, -е, -сы, -се,*** то после многоточия в целях экономии места ставится только один из этих четырех вариантов — вариант ***-ы***. Например, *колыбельный* — бишек... -ы; *колыбельная песня* — бишек җыры; *производственный* — җитештерү... -ы, эшләп чыгару... -ы; производство... -ы; *производственные отношения* — җитештерү мөнәсәбәтләре; *производственный процесс* — производство процессы.

Составители словаря при передаче русских отымённых прилагательных пользовались также и другими известными способами передачи их на татарский язык, например, посредством наречий на ***-ча, -чә*** на ***-лата, -ләтә,*** сочетанием имени существительного с послелогом „*белән*", имени существительного в местном падеже и т. д.

В подобных случаях, для того чтобы показать, что дальше следует определяемое существительное, ставится также многоточие. Например, *денежный* — акчалата...; *денежная помощь* — акчалата ярдәм; *вещевой* — әйберләтә..., әйберләр белән...; *вещевое довольствие* — әйберләтә тәэмин итү, әйберләр белән тәэмин итү; *дружеский* — дусларча...; *дружеский привет* — дусларча сәлам; *лабазный* — лабазда...; *лабазная торговля* — лабазда сату итү и т. д.

Прилагательные типа *литературный, классовый, научный* передаются существующими в татарском языке формами әдәби, сыйнфый, гыйльми, фәнни и т. п. Например, *классовая борьба* — сыйнфый көрәш; *научная работа* — фәнни эш; *литературное произведение* — әдәби әсәр.

Заимствованные относительные прилагательные типа *актуальный, социалистический, объективный, революционный* в словаре переданы при помощи суффиксов ***-аль, -ик, -ив, -ион*** и т. д. Например, *актуальный* — актуаль; *социалистический* — социалистик; *объективный* — объектив; *революционный* — революцион и др.

# ТӨЗҮЧЕЛӘРДӘН

Сүзлекне төзегәндә рус сүзләренең мәгънәләрен татарча мөмкин кадәр тулы һәм дөрес итеп бирү төп максат итеп куелды. Аерым алганда, рус сүзләренә эквивалент итеп китерелә торган татар сүзләрен грамматик яктан теләсә нинди җөмләдә кулланырлык итеп формалаштыруга зур игътибар бирелде.

Рус телендә исемнәрдән ясалган нисби сыйфатларны татар әдәби телендә нинди формаларда бирү мәсьәләсе шактый зур кыенлыклар тудыра. Андый нисби сыйфатларны татар әдәби телендә төрлечә бирергә мөмкин. Беренчедән, аларның кайберләре татар телендә исемнәргә *-лы, -ле, -лык, -лек, -гы, -ге* һ. б. аффикслар кушып ясалган сыйфатлар белән бирелә; мәсәлән, *летний* — җәйге; *летнее платье* — җәйге күлмәк; *солнечный день* — кояшлы көн. Икенчедән, әгәр дә рус телендәге нисби сыйфат татар телендә бернинди дә формаль күрсәткеч яки кушымча белән бирелә алмаса, аның мәгънәләре татарча контекстта аергыч функциясен үти торган баш килештәге исем белән бирелә. Мәсәлән, русча *каменный дом* дигән сүз тезмәсе татарча *таш өй* дип тәрҗемә ителә. Бу очракта русча *каменный* сүзенә татарча *таш* сүзе, *дом* сүзенә *өй* сүзе туры килә. Димәк, рус телендәге *каменный* нисби сыйфатына татар телендә баш килеш формасында аергыч функциясен үтәүче *таш* дигән исем туры килә. Ләкин татар телендә баш килеш формасындагы исем җөмләдән тыш алынганда бервакытта да сыйфат функциясен үти алмый. Шуңа күрә аның аергыч функциясендә килүен һәм аннан соң шул сүз тарафыннан ачыклана торган аерылмыш килүен күрсәтү өчен сүзлектә, шул типтагы кайбер башка сүзлекләрдәгечә, күп нокта куелды; мәсәлән, *каменный* — таш...; *каменный дом* — таш өй; *деревянный* — агач...; *деревянный дом* — агач өй; *стеклянный* — пыяла...; *стеклянный стакан* — пыяла стакан һ. б.

Әгәр дә ачыкланып килә торган исемнәр *-ы, -е, -сы, -се* тартым кушымчаларын ала торган булсалар, урынга экономия ясауны күздә тотып, аларның барысын да күрсәтеп тормыйча, күп ноктадан соң 3 нче зат тартым кушымчасы *-ы* гына куелды; мәсәлән, *колыбельный* — бишек... -ы; *колыбельная песня* — бишек җыры; *производственный* — җитештерү... -ы; эшләп чыгару... -ы; производство... -ы; *производственные отношения* — җитештерү мөнәсәбәтләре; *производственный процесс* — производство процессы.

Сүзлектә рус телендәге кайбер нисби сыйфатлар татар теленә хас булган башка чаралар белән дә, мәсәлән, ***-ча, -чә, -лата, -ләтә*** формаларындагы рәвеш, *белән* бәйлеге кушып алынган исем һәм урын-вакыт килеше формасындагы исем белән бирелделәр. Бу очракларда да ачыклана торган аерылмыш урынына күп нокта куелды. Мәсәлән, *вещевой* — әйберләтә..., әйберләр белән...; *вещевое довольствие* — әйберләтә тәэмин итү, әйберләр белән тәэмин итү; *дружеский* — дусларча...; *дружеский привет* — дусларча сәлам; *лабазный* — лабазда...; *лабазная торговля* — лабазда сату итү и. т. д.

Рус телендәге *литературный, классовый, научный* тибындагы нисби сыйфатлар татар телендә яшәп килгән *әдәби, сыйнфый, гыйльми, фәнни* һ. б. формалар белән бирелде; мәсәлән, *классовая борьба* — сыйнфый көрәш; *научная работа* — фәнни эш; *литературное произведение* — әдәби әсәр.

*Актуальный, социалистический, объективный, революционный* кебек алынма нисби сыйфатлар сүзлектә ***-аль, -ив, -ик, -ион*** һ. б. аффикслар белән бирелде, мәсәлән, *актуальный* — актуаль, *социалистический* — социалистик, *объективный* — объектив, *революционный* — революцион һ. б.

## ЗНАКИ ПРЕПИНАНИЯ

(тыныш билгеләре)

, (запятая) в переводной части отделяет татарские слова с одинаковыми или очень близкими значениями.

; (точка с запятой) отделяет татарские слова с более далёкими значениями, а также пример от данного значения слова.

. (точка) ставится после арабских цифр при перечислении различных значений русского слова, в конце абзаца, а также после каждого фразеологического оборота.

: (двоеточие) ставится после русского слова в тех случаях, когда слово употребляется только в словосочетаниях.

... (многоточие) заменяет пропущенное слово или недосказанную часть слова.

— (тире) ставится между русскими и татарскими словами, а также между примерами и их переводами.

...- (многоточие и дефис) ставится перед татарским аффиксом, который по своему значению соответствует русскому слову.

I, II, III... — служат для различения омонимов.

1, 2, 3... — ставятся при перечислении значений русского слова.

а, б, в... — когда некоторые значения слова объединяются одним термином, толкования этих значений даются в скобках и отделяются друг от друга буквами.

◇ (ромб) ставится перед идиоматическими и фразеологическими оборотами.

# УСЛОВНЫЕ СОКРАЩЕНИЯ

(шартлы кыскартмалар)

*ав.*— авиация
*агр.*— агрономия
*анат.*— анатомия
*апт.*— аптекарское
*археол.*— археология
*архит.*— архитектура
*астр.*— астрономия
*безл.*— безличная форма (затланышсыз форма)
*биол.*— биология
*биохим.*— биохимическое
*бот.*— ботаника
*бран.*— бранное слово (әрләү сүзе)
*бухг.*— бухгалтерия
*ввод. сл.*— вводное слово (кереш сүз)
*вет.*— ветеринария
*вин.*— винительный падеж
*воен.*— военный термин (хәрби термин)
*вульг.*— вульгарное слово
*геогр.*— география
*геодез.*— геодезия
*геол* — геология
*гл.*— глагол (фигыль)
*горн.*— горное (тау эшендә кулланыла торган)
*грам.*— грамматика
*дат.*— дательный падеж
*детск.*— детское слово (балалар сүзе)
*дипл.*— дипломатия
*дореволю.*— дореволюционное (революциягә кадәр кулланылган сүз)
*др.*— другие (башкалар)
*ед.*— единственное число (берлек саны)
*ест.*— естествознание
*ж.*— женский род
*ж.-д.*— железнодорожное (тимер юл эшендә кулланыла торган термин)
*живоп.*— живопись
*загр.*— за границей
*знач.*— значение
*зоол.*— зоология
*ирон.*— иронически (көлеп әйтелә торган)
*искус.*— искусство
*истор.*— историческое (тарихи сүз)
к.— кара (смотри)
*канц.*— канцелярское (канцелярия эшендә кулланыла торган)
*книж.*— книжное (китап сүзе)
*ком.*— коммерческое
*кратк. ф-мы* — краткой формы
*кулин.*— кулинария
*ласк.*— ласкательное (иркәләү сүзе)
*лингв.*— лингвистика
*лит.*— литературоведение
*м.*— мужской род
*мат.*— математика
*мед.*— медицина
*межд.*— междометие (ымлык)
*метеор.*— метеорология
*местоим.*— местоимение (алмашлык)
*мин.*— минералогия
*миф.*— мифология
*мн.*— множественное число (күплек саны)
*многокр.*— многократный вид (кабатлаулы күренеш)
*мор.*— морское дело (диңгез эшендә кулланыла торган)
*муз.*— музыка
*нареч.*— наречие (рәвеш)
*нар.-поэт.*— народно-поэтическое
*науч.*— научное (фәнни)
*неодобр.*— неодобрительно
*нескл.*— несклоняемое слово (төрләнми торган сүз)
*несов.*— несовершенный вид
*обл.*— областное (җирле сөйләштә кулланыла торган)
*однокр.*— однократный вид
*отриц.*— отрицание, отрицательный
*офиц.*— официальное (рәсми сүз)
*охот.*— охотничье (аучылык термины)
*п.*— падеж (килеш)
*перен.*— переносное значение (сүзнең күчерелмә мәгънәсе)
*плот.*— плотничье дело (балта осталыгы эше)
*повел. накл.*— повелительное наклонение (боерык фигыль)
*погов.*— поговорка (әйтем)
*полит.*— политика
*порт.*— портновское дело
*посл.*— пословица (мәкаль)
*поэт.*— поэтическое
*предл.*— предложный падеж
*презрит.*— презрительно
*пренебр.*— пренебрежительно (кимсетеп әйтү сүзе)
*прил.*— имя прилагательное (сыйфат)
*простореч.*— просторечие (халык телендә кулланыла торган)
*псих.*— психология
*публиц.*— публицистика
*радио* — радиотехника
*разг.*— разговорное (сөйләшү телендә кулланыла торган)
*рел.*— религиозное (дини сүз)
*ритор.*— риторическое
*род.*— родительный падеж
*рыболов.*— рыболовное дело
*сад.*— садоводство

*сапож.*— сапожное дело
*сказ.*— сказуемое (хәбәр)
*собир.*— собирательное
*сов.*— совершенный вид
*спец.*— специальное (махсус термин)
*спорт.*— спортивное (спорт термины)
*ср.*— средний род
*сравн. ст.*— сравнительная степень (чагыштыру дәрәҗәсе)
*старин.*— старинное
*столяр.*— столярное дело
*страд.*— страдательный залог (төшем юнәлеше)
*сущ.*— имя существительное (исем)
*с.-х.*— сельское хозяйство
*театр.*— театральное (театр һәм сәхнә өлкәсендә кулланыла торган)
*текст.*— текстильное (туку эшендә кулланыла торган)
*тех.*— техника
*тип.*— типографское дело (типография эшендә кулланыла торган)
*торг.*— торговое (сәүдә эшендә кулланыла торган)
*торж.*— торжественное
*увелич.*— увеличительное
*уменьш.*— уменьшительное
*уничижит.*— уничижительное
*устар.*— устарелое (искергән сүз)
*фам.*— фамильярное (игътибарсыз, илтифатсыз әйтелгән сүз)
*фарм.*— фармацевтическое
*физ.*— физика
*физиол.*— физиология
*филос.*— философия
*фин.*— финансовое
*фольк.*— фольклор (халык иҗаты)
*фот.*— фотография
*хим.*— химия
*церк.*— церковное (чиркәү сүзе)
*ч.*— число (сан)
*шахм.*— шахматный термин (шахмат термины)
*школьн.*— школьное
*шутл.*— шутливое (шаярып әйтелә торган сүз)
*эвф.*— эвфемистически
*эк.*— экономика
*эл.*— электричество
*этногр.*— этнография
*юр.*— юридический термин
*һ. б.*— һәм башкалар

**РУССКИЙ АЛФАВИТ**

(рус алфавиты)

А Б В Г Д Е Ж З И Й К Л М Н

О П Р С Т У Ф Х Ц Ч Ш Щ Ъ

Ы Ь Э Ю Я